# А

**А I** *ср. нескл.* — а хәрефенең һәм а авазының исеме. ◇ **От а до зет** — башыннан ахырына кадәр. **Кто сказал а, тот должен сказать б** — „а“сын әйткән кеше, „б“сын да әйтергә тиеш (фикер йөртүдә һәм эштә эзлекле булырга кирәклек турында әйтелә).

**А II** *союз* — 1. ә, исә, бәлки; *поезд уходит через час, а ты всё ещё не готов* — поезд бер сәгатьтән китә, ә син әле һаман әзер түгел; 2. ләкин, әмма; *прошло много времени с тех пор, а я всё помню* — аннан соң күп вакытлар үтеп китте, ләкин мин барысын да хәтерлим; 3. ә; *что ты сегодня делаешь; а завтра, а послезавтра?* — бүген син ни эшлисең; ә иртәгә, ә берсекөнгә? ◇ **А то** — юкса, югыйсә; я булмаса, әллә; *спеши, а то опоздаешь* — ашык, югыйсә соңга калырсың; *поздно уж туда идти, а то пойдём?* — анда барырга соң инде, әллә барабызмы?

**А III** *вопросит. частица* — ә; *что ты сказал, а?* — син нәрсә дидең, ә?

**А IV** *межд.* — 1. әәә,..; *а, это вы, Иван Иванович!* — әәә, Иван Иванович, бу сезмени! 2. әй; *а, была не была, пойду!* — әй, ни булса булыр, киттем!

**АБАЖУ'Р** *м.* — абажур, лампа калпагы.

**АББА'Т** *м. церк.* — аббат (1. католиклар монастыренең башлыгы; 2. Франциядә католиклар рухание).

**АБДИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — абдикация (тәхеттән ваз кичү; властьтан, урыннан төшү).

**АБЕРРАЦИО'ННЫЙ** — аберрацион, аберрация...-ы; *аберрационное явление* — аберрация күренеше, аберрацион күренеш.

**АБЕРРА'ЦИЯ** *ж.* — аберрация, тайпылыш, авышу, читкә китү (1. *астр.* җирнең әйләнүе тәэсирендә йолдызларның үз урыннарыннан авышкан кебек булып күренүләре; 2. *биол.* организмның нормаль төзелештән авышуы; 3. *перен.* фикер йөртүдә ялгышу, хакыйкатьтән читкә тайпылу).

**АБЗА'Ц** *м.* — 1. *(отступ)* кызыл юл, яңа юл (текстның яки аның кисәгенең башка юллардан эчкәрәк кертеп башланган беренче юлы); 2. *(часть текста)* абзац (текстның ике кызыл юл арасындагы өлеше).

**АБИССИ'НЕЦ** *м.* — абиссинияле.

**АБИССИ'НКА** *ж.* — абиссинияле хатынкыз.

**АБИССИ'НСКИЙ** — абиссин...-ы; *абиссинский язык* — абиссин теле.

**АБИССИ'НЦЫ** *мн.* — абиссиниялеләр, Абиссиния халкы.

**АБИТУРИЕ'НТ** *м. дореврл.* — абитуриент (урта мәктәптә чыгарылыш экзаменнары тотучы укучы).

**АБОЛИЦИОНИ'СТ** *м.* — аболиционист (коллыкны бетерү тарафдары; аерым очракларда — берәр законны бетерү тарафдары).

**АБОЛИ'ЦИЯ** *ж.* — аболиция (1. законны, карарны юкка чыгару; 2. судка бирелгән эшне гафу итү тәртибендә туктату).

**АБОНЕМЕ'НТ** *м.* — абонемент, абунә (1. билгеле бер срок дәвамында хак түләп берәр нәрсәдән, мәсәлән, телефоннан, файдалану хокукы; 2. шул хокукны раслый торган документ). ◇ **Сверх абонемента** — 1. абонемент белән шарт ителгәннән тыш; 2. *разг. шутл.* нормадан тыш, рөхсәт ителгәннән тыш.

**АБОНЕМЕ'НТНЫЙ** — абонемент...-ы; *абонементный билет* — абонемент билеты.

**АБОНЕ'НТ** *м.* — абонент, абунәче, абонемент иясе.

**АБОНЕ'НТНЫЙ** — абонентлар...-ы; *абонентный отдел* — абонентлар бүлеге.

**АБОНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — абонемент буенча алу.

**АБОНИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. абонемент алу; 2. *страд.* абонемент буенча алыну.

**АБОРИГЕ'Н** *м.* — абориген, җирле халык, илнең төп халкы.

**АБОРИГЕ'ННЫЙ** — җирле, төп; *аборигенное население* — җирле халык.

**АБО'РТ** *м.* — аборт, бала төшерү, бала төшертү.

**АБОРТИ'ВНЫЙ** — 1. аборт...-ы; бала төшерү (төшертү)...-ы; *абортивные средства* — аборт чаралары, бала төшерү чаралары; 2. *мед.* абортив (авыруның барышына тиз һәм кискен үзгәреш кертә торган); *абортивный метод лечения* — дәвалауда абортив метод; 3. *биол.* абортив, житлекмәгән; *абортивные органы растений* — үсемлекләрнең житлекмәгән органнары.

**АБРАЗИ'ВНЫЙ, АБРАЗИО'ННЫЙ** — абразив, шомарта торган, шомарту...-ы; *абразивные материалы* — абразив материаллар, шомарту материаллары (мәсәлән, пемза, наждак, төелгән пыяла кебек әйберләр).

**АБРАЗИ'ВЫ** *мн.* — абразивлар, абразив материаллар, шомарту материаллары.

**АБРАКАДА'БРА** *ж. мн.* нет — абракадабра (1. им-том иткәндә, тылсымлаганда кулланыла торган мәгънәсез сүзләр; 2. *перен.* мәгънәсез сүзләр, сафсата).

**АБРЕВИАТУ'РА** *ж.*, **АБРЕВИА'ЦИЯ** *ж.* — абревиатура (1. язуда һәм сөйләүдә шартлы рәвештә кыскартылган сүзләр, мәсәлән, „һәм башкалар" урынына „һ. б." дип кыскарту; 2. СССР, колхоз, Совнарком кебек ике яки берничә сүздән кыскартып ясалган сүз; 3. *муз.* нота язганда кулланыла торган кыскартмалар).

**АБРЕ'К** *м. истор.* — абрек (электә төньяк Кавказ халыкларында ыруыннан сөрелеп йортсыз-җирсез яшәгән яки юлбасарлык иткән кеше; соңыннан патша администрациясенә һәм рус гаскәрләренә каршы ялгыз көрәш алып барган кешене дә шулай атаганнар).

**АБРИКО'С** *м.* — абрикос, өрек (җимеше һәм агачы).

**АБРИКО'СНЫЙ** — абрикос...-ы, өрек...-ы; *абрикосная косточка* — абрикос төше.

**АБРИКО'СОВЫЙ** — абрикос...-ы; абрикостан ясалган; *абрикосовое варенье* — абрикос вареньесы.

**АБРИКОТИ'Н** *м.* — абрикотин, абрикос ликёры.

**А'БРИС** *м.* — абрис, предметның контуры, тышкы сызымы, гомуми кыяфәте; контур рәсем.

**АБРОГА'ЦИЯ** *ж.* — аброгация (искергән законны юкка чыгару).

**АБСЕНТЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет — абсентеизм (буржуаз илләрдә сайлауларга катнашудан, җыелышларга килүдән масса күләмдә баш тарту).

**АБСЕНТЕИ'СТ** *м.* — абсентеист, абсентеизм тарафдары (буржуаз илләрдә сайлауларга катнашудан, җыелышларга килүдән баш тартучы).

**АБСОЛЮ'Т** *м. филос.* — абсолют (идеалистик философиядә: галәмнең мәңгелек, үзгәрмәс, беренчел нигезе — алла, абсолют рух, абсолют идея).

**АБСОЛЮТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — абсолютизм, чикләнмәгән монархия.

**АБСОЛЮТИ'СТ** *м.* — абсолютист, абсолютизм тарафдары, абсолютизмны яклаучы.

**АБСОЛЮТИ'СТСКИЙ** — абсолютистлык ...-ы, монархистлык...-ы; *абсолютистские взгляды* — абсолютистлык (монархистлык) карашлары.

**АБСОЛЮ'ТНО** *нареч. разг.* — бөтенләй, һич, абсолют рәвештә; *это абсолютно невозможно* — бу һич мөмкин түгел.

**АБСОЛЮ'ТНЫЙ** — 1. абсолют, чикләнмәгән, шарт куелмаган; *абсолютное право* — чикләнмәгән хокук; 2. тулы; *абсолютный покой* — тулы тынычлык.

**АБСОРБИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. физ., хим.* — йоту, сеңдерү, суыру, абсорбцияләү.

**АБСОРБИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — йотылу, сеңдерелү, абсорбцияләнү.

**АБСО'РБЦИЯ** *ж. физ., хим.* — абсорбция, йоту, йотылу, сеңдерү, сеңдерелү, суыру, суырылу, эретү, эретелү.

**АБСТИНЕ'НТЫ** *мн.* — абстинентлар (спиртлы эчемлекләр эчүнең, аларны эшләп чыгаруның һәм сатуның бөтенләйгә тыелуын таләп итүчеләр).

**АБСТРАГИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — абстракцияләү, абстрактлаштыру (конкрет предметлардан гомуми, абстракт фикергә күчү).

**АБСТРАГИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. абстракциягә әйләнү, абстракцияләнү, абстрактлашу; 2. *страд.* абстрактлаштырылу.

**АБСТРА'КТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — абстрактлык.

**АБСТРА'КТНЫЙ** — 1. абстракт; *абстрактные понятия* — абстракт төшенчәләр; 2. абстракт, абстракциягә нигезләнгән; *абстрактный метод* — абстракт метод.

**АБСТРА'КЦИЯ** *ж.* — абстракция (1. фикер йөрткәндә предметның мөһим үзенчәлекләрен генә исәпкә алу; 2. абстракт төшенчә).

**АБСУ'РД** *м.* — абсурд, мәгънәсезлек (акылга ятышсыз, акылга сыймый торган нәрсә).

**АБСУ'РДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — абсурдлык, мәгънәсезлек, акылга сыймаслык булу.

**АБСУ'РДНЫЙ** — абсурд..., мәгънәсез, акылга сыймый торган; *абсурдный вывод* — абсурд нәтиҗә, мәгънәсез нәтиҗә.

**АБСЦЕ'СС** *м. мед.* — эренле шеш, эренле чуан.

**АБХА'ЗЕЦ** *м.* — абхазияле.

**АБХА'ЗКА** *ж.* — абхазияле хатын-кыз.

**АБХА'ЗСКИЙ** — абхаз...-ы; *абхазский язык* — абхаз теле.

**АБХА'ЗЦЫ** *мн.* — абхазиялеләр, абхаз халкы.

**АВАНГА'РД** *м.* — авангард, алдынгы отряд (1. гаскәрнең, флотның төп көчләрдән алда бара торган отряды; 2. берәр иҗтимагый группаның массаны үз артыннан ияртеп алып баручы алдынгы өлеше).

**АВАНГА'РДНЫЙ** — 1. авангардлар...-ы; алдынгы отрядлар...-ы; *авангардные бои* — авангардлар сугышы; 2. авангардлык...-ы; алдынгылык...-ы; *авангардная роль* — авангардлык (алдынгылык) роле.

**АВАНПО'СТ** *м.* — аванпост, алгы пост (төп көчләрдән алга куелган караул, сакчы отряд).

**АВА'НС** *м.* — аванс (1. киләчәктә бирeләчәк акча яки продукт исәбенә алдан биреп куелган өлеш; 2. берәр расход өчен алдан биреп куелган акча).

**АВАНСИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — аванс бирү, аванс итеп бирү.

**АВАНСИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. аванс алу, аванс алып кую; 2. *страд.* аванс бирелү, аванс итеп бирелү.

**АВА'НСОВЫЙ** — аванс...-ы; *авансовый отчёт* — аванс отчёты.

**АВА'НСОМ** *нареч.* — 1. аванс итеп, аванс рәвешендә, алачак исәбенә; 2. *перен.* алдан ук; *сказать авансом* — алдан ук әйтеп кую.

**АВАНСЦЕ'НА** *ж.* — авансцена, сәхнә алды (сәхнәнең пәрдә төшкәч тамаша залы ягында кала торган өлеше).

**АВАНТЮ'РА** *ж.* — авантюра (1. тәвәккәлгә корылган эш, уңышлы булачагын

алдан уйлап җиткермичә эшләнгән эш; 2. алдауга корылган эш; 3. *лит.* мажара).

**АВАНТЮРИ'ЗМ** *м. мн.* нет — авантюризм, авантюрачылык.

**АВАНТЮРИ'СТ** *м.* — авантюрист (авантюрага бирелгән кеше).

**АВАНТЮРИСТИ'ЧЕСКИЙ** — авантюристик, авантюрага корылган.

**АВАНТЮРИ'СТКА** *ж.* — авантюристка.

**АВАНТЮ'РНЫЙ** — 1. авантюралы; 2. *лит.* мажаралы, мажараларга бай; *авантюрный роман* — мажараларга бай роман.

**АВА'РЕЦ** *м.* — авар (Дагстанда яшәүче бер миллэт вәкиле).

**АВАРИ'ЙНЫЙ** — 1. авария...-ы; *аварийная рация* — авария рациясе; 2. аварияга очраган, һәлакәткә очраган.

**АВА'РИЯ** *ж.* — 1. авария, бәрелешү, ватылу, һәлакәт (самолётның, пароходның, машинаның һәм гомумән берәр җайланманың, корылманың, бина кебекләрнең берәр һәлакәткә очрап эштән чыгуы); 2. *мор. юр.* авария (пароходка авария булу сәбәпле килгән зарарлар, көтелмәгән расходлар); 3. *перен.* уңышсызлык, бәхетсезлек; *на этом деле он потерпел аварию* — бу эштә ул уңышсызлыкка очрады.

**АВА'РКА** *ж.* — авар хатын-кызы.

**АВА'РСКИЙ** — авар...-ы; *аварский язык* — авар теле.

**АВА'РЦЫ** *мн.* (*ед.* аварец) — аварлар, авар халкы.

**А'ВГИЕВЫ КОНЮ'ШНИ** — Авгий абзарлары (1. борынгы грек мифологиясендә — легендар Авгий патшаның күп еллар чистартылмаган ат абзарлары; 2. *перен.* үтә пычрак, үтә ташландык урын; күптән җыелып килгән пычраклык, бозыклык).

**АВГУ'Р** *м.* — авгур (1. борынгы Римда — кошларның очуына һәм сайравына карап күрәзәлек итүче, фалчы; 2. *перен.* алдакчы, шарлатан).

**А'ВГУСТ** *м.* — август.

**АВГУСТЕ'ЙШИЙ** *дореволь.* — галиҗәнап, олуг хөрмәтле (электә патша семьясы членнарына мөрәҗәгать иткәндә әйтелгән).

**А'ВГУСТОВСКИЙ** — август...-ы; *августовские дни* — август көннәре.

**АВЕНЮ'** *ср. нескл.* — авеню, киң урам (күбесенчә ике ягына агачлар утыртылган киң урам, көнбатыш илләрдә).

**АВИАБА'ЗА** *ж.* — авиабаза, авиация базасы.

**АВИАБО'МБА** *ж.* — авиабомба (самолётлардан ташлана торган бомба).

**АВИАГОРИЗО'НТ** *м.* — авиагоризонт (һава начар вакытта яки караңгы төндә очкан самолётның горизонтка карата торышын күрсәтә торган прибор).

**АВИАДЕСА'НТ** *м.* — авиадесант (самолёттан дошман территориясенә төшерелгән гаскәр).

**АВИАЗАВО'Д** *м.* — авиазавод, самолётлар ясау заводы.

**АВИАМЕТЕОСТА'НЦИЯ** *ж.* — авиаметеостанция (самолётлар өчен һава хәле турында хәбәр бирен тора торган станция).

**АВИАМОДЕЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — авиамоделизм (оча торган аппаратларның модельләрен ясау һәм очыртып карау).

**АВИАМОТО'Р** *м.* — авиамотор, самолёт моторы.

**АВИАНО'СЕЦ** *м.* — авианосец (диңгез флотында самолётларны палубадан очыртып җибәрү һәм төшерү өчен махсус рәвештә җайланган судно).

**АВИАПА'РК** *м.* — авиапарк (авиация паркы).

**АВИАПО'ЧТА** *ж.* — авиапочта.

**АВИАРАЗВЕ'ДКА** *ж.* — авиаразведка, авиация разведкасы.

**АВИАСИГНА'ЛЬНЫЙ** — һава сигналы бирү...-ы; *авиасигнальные средства* — һава сигналы бирү чаралары.

**АВИАСПО'РТ** *м.* — авиаспорт, очу спорты.

**АВИА'ТОР** *м.* — лётчик, очучы.

**АВИА'ТОРСКИЙ** — авиатор...-ы, авиаторлык...-ы, очучылык...-ы; *авиаторская способность* — авиаторлык (очучылык) сәләте.

**АВИАЦИО'ННЫЙ** — авиация...-ы; *авиационная база* — авиация базасы.

**АВИА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — авиация (1. һавадан авыррак аппаратларда очу теориясе һәм практикасы; 2. һава флоты).

**АВИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — авизо җибәрү (бухгалтерия тарафыннан ясалган операцияләр турында клиентка белдерү).

**АВИ'ЗО** *ср. нескл.* — авизо (1. вексель, товар яки акча җибәрү турында белдерү хаты; 2. разведка ясау һәм йомышка йөрү хезмәтен үти торган тиз йөрешле кечкенә хәрби пароход; Франция флотында хәзерге көндә дә бар).

**АВИТАМИНО'ЗЫ** *мн.* — авитаминозлар (азыкта витаминнар булмау яки җитмәү сәбәпле була торган авырулар, мәс., зәңгелә авыруы).

**АВО'СЬ** *мод. сл.* — бәлки, ихтимал. ◇ **На авось** — тәвәккәлләп; булса булыр, булмаса юк дип. **Авось да небось** или **авось, небось да как-нибудь** — ничек туры килсә шулай; тисә тиенгә, тимәсә ботакка.

**АВРА'Л** *м.* — аврал (1. *мор.* корабльдә барлык команданың катнашы белән үткәрелә торган эш; 2. *перен.* көтмәгәндә килеп чыккан яки үз вакытында үтәлмәгән эшне башкару өчен барлык работникларны мобилизацияләү).

**АВРА'ЛЬНЫЙ** — аврал...-ы; *авральная вахта* — аврал вахтасы.

**АВРО'РА** *ж. устар.* — иртәнге шәфәкъ.

**АВСТРАЛИ'ЕЦ** *м.* — австралияле.

**АВСТРАЛИ'ЙКА** *ж.* — австралияле хатын-кыз.

**АВСТРАЛИ'ЙЦЫ** *мн.* — австралиялеләр, Австралия халкы.

**АВСТРА'ЛЬНЫЙ** — көньяк...-ы, көньяктан исә торган, көньякта була торган.

**АВСТРИ'ЕЦ** *м.* — австрияле.

**АВСТРИ'ЙКА** *ж.* — австрияле хатын-кыз.

**АВСТРИ'ЙСКИЙ** — 1. Австрия...-ы; *австрийская столица* — Австрия башкаласы; 2. австрияләләр...-ы; *австрийский обычай* — австрияләләр гадәте.

**АВСТРИ'ЙЦЫ** *мн.* — австрияләләр, Австрия халкы.

**АВТАРКИ'Я** *ж. мн.* нет — автаркия (эчке рынокны капиталистик монополияләргә беркетү юлы белән милли хуҗалыкны агрессив сугышлар хәзерләүгә яраклаштыруны күздә тоткан империалистик экономик политика).

**АВТЕНТИ'ЧЕСКИЙ, АВТЕНТИ'ЧНЫЙ** — төп, асыл, чын; *автентичный текст закона* — законның төп (асыл) тексты.

**АВТО'** *ср. нескл.* — автомобиль.

**АВТОБА'ЗА** *ж.* — автобаза, автомобильләр базасы.

**АВТОБИОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — автобиографик.

**АВТОБИОГРАФИ'ЧНЫЙ** — автобиография характерындагы.

**АВТОБИОГРА'ФИЯ** *ж.* — автобиография, тормыш юлы, тәрҗемәи хәл (берәүнең үз тормышы турындагы язмасы).

**АВТОБЛОКИРО'ВКА** *ж.* — автоблокировка (поездларның ике станция арасында йөрүләрен регулярлаштыра торган автоматик аппаратлар системасы).

**АВТО'БУС** *м.* — автобус.

**АВТО'БУСНЫЙ** — автобус...-ы, автобуслар...-ы; *автобусный гараж* — автобуслар гаражы. ◇ **Между Казанью и Мамадышом открылось автобусное сообщение** — Казан белән Мамадыш арасында автобус йөри башлады (автобус юлы ачылды).

**АВТОВАКЦИ'НА** *ж. мед.* — автовакцина (авыруның үзеннән алынган микроблардан хәзерләнгән вакцина).

**АВТОГАРА'Ж** *м.* — автогараж (автомобильләр гаражы).

**АВТОГЕ'ННЫЙ** — автоген юлы белән эретеп...; *автогенная сварка* — автоген юлы белән эретеп ялгау (металларны янып торган газ ялкынында эретеп ялгау).

**АВТО'ГРАФ** *м.* — автограф (1. авторның үз кульъязмасы; берәүнең үз язмасы яки үз имзасы; 2. үзе яза торган прибор).

**АВТОГРАФИ'ЧЕСКИЙ, АВТОГРАФИ'ЧНЫЙ** — автографик, автор үзе язган.

**АВТОГРА'ФИЯ** *ж.* — автография (кульъязманы, сызманы, рәсемне нәкъ үзенә охшатып күчерү).

**АВТОДАФЕ'** *ср. нескл.* — 1. автодафе (урта гасырларда Испаниядә еретикларны һәм аларның әсәрләрен инквизиция хөкеме буенча халык алдында яндыру); 2. *книж. шутл.* яндыру, яндырып бетерү; *всю переписку он подверг автодафе* — барлык хатларын ул яндырып бетерде.

**АВТОЗАВО'Д** *м.* — автозавод, автомобиль заводы.

**АВТОКА'МЕРА** *ж.* — автокамера (автомобиль шинының һава өрдереп тутырыла торган эчке катламы).

**АВТОКОЛО'ННА** *ж.* — автоколонна, автомашиналар колоннасы.

**АВТОКРА'Н** *м. тех.* — автокран (авыр йөкләрне күтәреп бер урыннан икенче урынга күчерү өчен автоматик кран).

**АВТОКРА'Т** *м.* — автократ (хокукы чикләнмәгән патша).

**АВТОКРА'ТИЯ** *ж.* — автократия, самодержавие (чикләнмәгән югары власть бер генә кеше кулында булган идарә системасы).

**АВТО'Л** *м. мн.* нет — автол (нефтьтән эшләп чыгарыла торган май; машиналарны майлау өчен кулланыла).

**АВТОЛЕСОВО'З** *м.* — автолесовоз (агач материаллары ташый торган махсус автомобиль).

**АВТОМА'Т** *м.* — автомат (1. эчке механизм ярдәмендә үзеннән-үзе эшли торган аппарат; 2. *воен.* автомат рәвештә ата торган корал; 3. *перен.* уйламыйча, машина кебек эшләүче кеше).

**АВТОМАТИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — автоматлаштыру, автоматлашу, автоматлаштырылу.

**АВТОМАТИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — автоматлаштыру, автоматка әйләндерү.

**АВТОМАТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. автоматлашу, автоматка әйләнү; 2. *страд.* автоматлаштырылу, автоматка әйләндерелү.

**АВТОМАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — автоматизм, автоматлык (эшнең яки хәрәкәтнең аңсыздан, ирексездән эшләнүе).

**АВТОМАТИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — автоматик рәвештә, үзеннән-үзе.

**АВТОМАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. автомат..., үзеннән-үзе эшли торган; *автоматическое ружьё* — автомат мылтык; 2. автоматик, машинадай, уйламыйча эшләнгән, ирексез эшләнгән; *автоматическое движение* — автоматик хәрәкәт.

**АВТОМАТИ'ЧНЫЙ** — *к.* автоматический 2.

**АВТОМА'ТЧИК** *м.* — автоматчик (1. автомат аппаратта эшләүче эшче; 2. автомат мылтыктан атучы).

**АВТОМАШИ'НА** *ж.* — автомашина, автомобиль.

**АВТОМОБИЛЕСТРОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — автомобильләр эшләп чыгару, автомобильләр ясау.

**АВТОМОБИЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — автомобилизм, автомобиль спорты.

**АВТОМОБИЛИ'СТ** *м.*, **АВТОМОБИЛИСТ'КА** *ж.* — автомобиль спорты һәвәскәре.

**АВТОМОБИ'ЛЬ** *м.* — автомобиль.

**АВТОМОБИ'ЛЬНЫЙ** — автомобиль...-ы; *автомобильный завод* — автомобиль заводы.

**АВТОНОМИ'СТ** *м.* — автономист, автономия тарафдары.

**АВТОНО'МИЯ** *ж. полит.* — автономия, үзидарә (нинди дә булса бер өлкәнең үзенең законнары нигезендә идарә ителүгә һәм үзенең дәүләт органнарын булдыруга хокукы).

**АВТОНО'МНЫЙ** — автономияле.

**АВТОПИЛО'Т** *м.* — автопилот (самолётны автоматик рәвештә йөртү өчен кулланыла торган җайланма).

**АВТОПОРТРЕ'Т** *м.* — автопортрет (художникның үзе ясаган үз рәсеме).

**А'ВТОР** *м.* — автор (фәнни, әдәби әсәр язучы яки берәр нәрсә уйлап чыгаручы).

**АВТОРЕМО'НТНЫЙ** — авторемонт...-ы; *авторемонтные мастерские* — авторемонт мастерскойлары.

**АВТОРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — авторлаштыру (үз әсәренең тәрҗемә итүгә рөхсәт, вәкаләт бирү).

**АВТОРИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— авторлаштыру (1. берәүгә нинди дә булса бер эшне башкаруга рөхсәт, вәкаләт бирү; 2. үзенең әсәренңе, уйлап чыгарганыңны таратуга ризалык бирү; үзеңнең әсәреңнең тәрҗемәсен яхшы дип табу).

**АВТОРИТА'РНЫЙ**—авторитар (1. властька сукырларча буйсынуга нигезләнгән; 2. властьлы, үзенең авторитетын ныгытуга омтылучы).

**АВТОРИТЕ'Т** *м.* 1. *только ед.*— авторитет, абруй; 2. ышаныч казанган кеше, танылган кеше; *этот учёный — авторитет в своей области* — бу галим — үз өлкәсендә танылган кеше.

**АВТОРИТЕ'ТНО** *нареч.* — авторитет белән, ышандырырлык итеп.

**АВТОРИТЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет—1. авторитетлылык, авторитетлы булу, абруйлылык; игътибарлылык; 2. ышанычлылык.

**АВТОРИТЕ'ТНЫЙ — 1.** *(пользующийся авторитетом)* авторитетлы, абруйлы, танылган; 2. ышанычлы; *из авторитетных источников* — ышанычлы чыганаклардан.

**А'ВТОРСКИЕ** *только мн.* — гонорар, әсәр өчен түләнгән акча.

**А'ВТОРСКИЙ**—авторлык...-ы, автор...-ы, авторлар...-ы; *авторское право* — авторлык хокукы; *авторский коллектив* — авторлар коллективы; *авторская ошибка* — автор хатасы.

**А'ВТОРСТВО** *ср. мн.* нет — авторлык.

**АВТОСА'НИ** *только мн.*— авточана (алгы тәгәрмәчләре астына чаңгылар куелган автомобиль).

**АВТОСТРА'ДА** *ж.*— автострада (автомобильләр йөрү өчен генә эшләнгән киң шоссе).

**АВТОТО'МИЯ** *ж.* — автотомия, үз-үзен гарипләү (кайбер хайваннарның, мәс., кәлтәнең, икенче бер хайван эләктереп алган вакытта шул эләктерелгән агзаларын үз ирекләре белән өзеп калдырып китүләре).

**АВТОТРА'НСПОРТ** *м.* — автотранспорт, автомобиль транспорты.

**АВТОХТО'ННЫЙ** — жирле, төп (билгеле бер илдә, өлкәдә, урында барлыкка килгән).

**АВТОХТО'НЫ** *ед.* нет — 1. автохтоннар, аборигеннар, жирле халыклар, төп халыклар; 2. *биол.* жирле фауна һәм флора (шушы урында барлыкка килгән хайваннар һәм үсемлекләр төре).

**АВТОШИ'НА** *ж.*— автошина, автомобиль шины.

**АГА'** I *межд.*— әһә; *ага, попался!* — әһә, эләктеңме!

**АГА'** II *частица простореч.* — әйе; *ты помнишь его? — Ага!* синең исеңдәме ул?— Әйе!

**АГА'ВА** *ж. бот.* — агава (тропик үсемлек).

**АГА'Т** *м.*— ахак (минерал).

**АГГЛЮТИНАТИ'ВНЫЙ ЯЗЫК** *лингв.* — агглютинатив тел, ялганмалы тел (мәс., татар теле).

**АГГЛЮТИНА'ЦИЯ** *ж.* — агглютинация, ялгау, ялгану (1. *лингв.* сүзләрнең тамырга аффикслар кушу юлы белән ясалышы һәм төрләнеше, мәс., татар телендә: авыл-лар-ыбыз-да; 2. *мед.* бактерияләрнең бергә укмашып төпкә утырулары).

**АГ(Г)РЕГА'Т** *м.* — аг(г)регат (1. төрле яки бер төрле кисәкләрнең механик катнашмасы; 2. гомуми бер эшне башкару өчен бергә кушылган ике яки берничә машина; 3. катлаулы машинаның бер кисәге, мәс., автомобиль двигателе).

**А'ГЕ'НТ** I *м.*— агент, вәкил (берәр кешенең, шулай ук учреждениенең яки предприятиенең тапшыруы буенча эш итүче кеше).

**А'ГЕ'НТ** II *м.* — агент, шпион, шымчы, диверсант.

**А'ГЕ'НТ** III *м. физ., хим.*— агент, сәбәпче, этәргеч (табигатьтә яки организмда теге яки бу күренешләрне китереп чыгара торган сәбәп).

**АГЕ'НТСКИЙ** — агентлык...-ы; *агентская контора* — агентлык конторасы.

**А'ГЕНТСТВО** *ср.* — агентлык, агентство.

**АГЕНТУ'РА** *ж. мн.* нет — 1. агентлык (эше яки вазифасы); 2. *собир.* агентлар; 3. агентура (буржуаз дәүләтләрнең шпионнары һәм диверсантлары).

**АГЕНТУ'РНЫЙ** — агентура...-ы, шпионлык...-ы, шымчылык...-ы; *агентурные сведения* — шпионлык (шымчылык) мәгълүматлары.

**АГИТА'ТОР** *м.*—агитатор, агитация ясаучы.

**АГИТА'ТОРСКИЙ** — агитаторлык...-ы, агитаторлар...-ы; *агитаторские способности* — агитаторлык сәләтләре; *агитаторский коллектив* — агитаторлар коллективы.

**АГИТАЦИО'ННЫЙ** — агитация...-ы, агитацион; *агитационный плакат* — агитация плакаты.

**АГИТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — агитация, аңлату, өндәү.

**АГИТБРИГА'ДА** *ж.* — агитбригада, агитаторлар бригадасы.

**АГИТИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. агитация ясау, агитация алып бару; 2. димләү.

**АГИ'ТКА** *ж. разг.* — агитка, агитация чарасы (мәс., плакат).

**АГИТКОЛЛЕКТИ'В** *м.* — агитколлектив, агитаторлар коллективы.

**АГИТПРО'П** *м.* — агитпроп, агитация-пропаганда бүлеге.

**АГИТПУ'НКТ** *м.* — агитпункт, агитация пункты.

**А'ГНЕЦ** *м.* — 1. *церк.* корбан бәрәне; 2. *перен.* юаш, гаепсез кеше.

**АГНОСТИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — агностицизм (объектив дөньяны һәм аның закончалыкларын танып-белү мөмкин түгел дип раслаучы идеалистик философик тәгълимат).

**АГОНИЗИ'РОВАТЬ, АГОНИ'РОВАТЬ** *несов.*— агониядә булу.

**АГО'НИЯ** *ж.*— 1. *мед.* агония, үлем газабы; 2. *перен.* ахыргы тапкыр тырышып карау, көч куеп карау.

**АГРА'РИИ** *мн.* (*ед.* аграрий) — 1. эре алпавытлар, жир биләүчеләр; 2. аграрийлар (эре жир биләүчелекне яклаучы реакцион партия члennары).

**АГРА'РНИК** *м.* — аграрник, аграр мәсьәләләр белгече.

**АГРА'РНЫЙ** — аграр; *аграрный вопрос* — аграр мәсьәлә.

**АГРЕМА'Н, АГРЕМЕ'НТ** *м.* — агреман (бер ил хөкүмәтенең икенче бер илнең дипломатия вәкилен кабул итүгә ризалык белдерүе).

**АГРЕССИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — агрессивлык.

**АГРЕССИ'ВНЫЙ** — агрессив, басып алу ...-ы; *агрессивная политика* — агрессив политика, басып алу политикасы.

**АГРЕ'ССИЯ** *ж.* — агрессия, һөҗүм, басып алу.

**АГРЕ'ССОР** *м.* — агрессор, һөҗүм итүче як, басып алучы.

**АГРИКУЛЬТУ'РА** *ж. мн.* нет — 1. агрикультура, игенчелек; 2. агрикультура (игенчелекнең техникасын яхшырту чаралары һәм алымнары).

**АГРИКУЛЬТУ'РНЫЙ** — агрикультура...-ы, игенчелек...-ы; *агрикультурные мероприятия* — агрикультура (игенчелек) чаралары.

**АГРОБИОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — агробиологик, агробиология...-ы; *агробиологическая наука* — агробиологик фән, агробиология фәне.

**АГРОБИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — агробиология (агрономия эшләрен биология нигезендә алып бару турындагы фән).

**АГРОКРУЖО'К** *м.* — агротүгәрәк.

**АГРОЛЕСОМЕЛИОРА'ЦИЯ** *ж.* — агролесомелиорация (югары уңыш тәэмин итү өчен урман полосалары утырту, сугару, сазлыкларны киптерү кебек чаралар системасы).

**АГРОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — агрология (туфрак белеменең бер өлеше).

**АГРОМА'КСИМУМ** *м.* — агромаксимум (авыл хуҗалыгы эшләрен алып бару өчен кирәк булган агрономик чараларның, белемнәрнең максимумы).

**АГРОМЕЛИОРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — агромелиорация (җирне сугару, киптерү, юылудан саклау һәм гомумән эшкә яраксыз җирләрне яхшырту).

**АГРОМЕРОПРИЯ'ТИЯ** *мн.* — агрочаралар.

**АГРОМЕТЕОРОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — агрометеорология (метеорологиянең үсемлекләр үсешендә метеорологик шартларның (һава торышының) ролен өйрәнә торган бүлеге).

**АГРОМИ'НИМУМ** *м.* — агроминимум (авыл хуҗалыгы өчен кирәк булган агрономик чараларның, белемнәрнең минимумы).

**АГРОНО'М** *м.* — агроном (авыл хуҗалыгы белгече, авыл хуҗалыгы производствосын оештыручы).

**АГРОНОМИ'ЧЕСКИЙ** — 1. агрономнар...-ы; *агрономический съезд* — агрономнар съезды; 2. агрономик, агрономия...-ы; *агрономические мероприятия* — агрономик чаралар; *агрономический институт* — агрономия институты.

**АГРОНО'МИЯ** *ж. мн.* нет — агрономия (игенчелек һәм авыл хуҗалыгы турындагы фән).

**АГРОПО'МОЩЬ** *ж. мн.* нет — агроярдәм (авыл хуҗалыгын күтәрүгә юнәлдерелгән ярдәмче чаралар).

**АГРОПРОПАГА'НДА** *ж. мн.* нет — агропропаганда (авыл хуҗалыгы эшләрен фәнни нигездә алып баруга өндәү).

**АГРОПУ'НКТ** *м.* — агропункт, агрономия пункты.

**АГРОТЕ'ХНИК** *м.* — агротехник.

**АГРОТЕ'ХНИКА** *ж. мн.* нет — агротехника (игенчелектә фәнни алымнар).

**АГРОТЕХНИ'ЧЕСКИЙ** — агротехник, агротехника...-ы; *агротехнические мероприятия* — агротехник чаралар.

**АГРОТЕХПРОПАГА'НДА** *ж.* — агротехника пропагандасы.

**АГРОХИ'МИЯ** *ж. мн.* нет — агрохимия.

**АД** *м. мн.* нет — 1. *рел.* тамуг, җәһәннәм; 2. *перен.* авырлык, газап, михнәт; *народы не хотят нового ада войны* — халыклар яна сугыш михнәтләрен теләми.

**АДАМА'НТ** *м.* — 1. алмаз, бриллиант; 2. *перен.* адамант (фикерендә нык торучы кеше).

**АДА'МОВА ГОЛОВА'** — 1. к. голова; 2. *зоол.* кисекбаш(күбәләк); 3. *бот.* канкортчыч (үсемлек).

**АДА'МОВО Я'БЛОКО** — чалу сөяге, бугаз төене (кешедә).

**АДАПТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — адаптация, җайлану, ипләшү; җиңеләйтү, яраштыру.

**АДА'ПТЕР** *м. тех.* — адаптер (граммофон пластинкаларына язылганнарны радиоалгычның репродукторы аркылы тапшыру приборы).

**АДАПТИ'РОВАННЫЙ ТЕКСТ** — җайлаштырылган текст, җиңеләйтелгән текст (аз хәзерлекле укучылар өчен).

**АДВЕРБИА'ЛЬНЫЙ** *грам.* — адвербиаль, рәвешсыман, рәвеш үзлекләре булган, рәвеш мәгънәсе булган.

**АДВОКА'Т** *м.* — *юр.* адвокат, яклаучы.

**АДВОКА'ТСКИЙ** — 1. адвокат(лык)...-ы; *адвокатская защита* — адвокат яклавы; 2. *перен.* адвокатларча, бик оста; *адвокатское выступление* — адвокатларча чыгыш, бик оста чыгыш.

**АДВОКА'ТСТВОВАТЬ** *несов. разг.* — адвокатлык итү, адвокат булу.

**АДВОКАТУ'РА** *ж. мн.* нет — 1. *(деятельность адвоката)* адвокатлык; 2. *собир.* адвокатлар.

**АДЕКВА'ТНЫЙ** — к. адэкватный.

**АДЕ'ПТ** *м.* — адепт (1. нинди дә булса бер тәгълиматның, сектаның һ. б. серләрен белүче; 2. нинди дә булса бер тәгълиматның, идеянең иярчене, тарафдары).

**АДИНАМИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — адинамия (картлык, озак авыру яисә ачыгу сәбәпле туган көчсезлек, зәгыйфьлек).

**АДМИНИСТРАТИ'ВНЫЙ** — 1. администрация...-ы; *административный отдел* — администрация бүлеге; 2. административ; *административные меры* — административ чаралар; 3. администраторлык...-ы; *административные способности* — администраторлык сәләтләре.

**АДМИНИСТРА'ТОР** *м.* — администратор (1. идарә итүче, җаваплы башкаручы; 2. идарә итүгә сәләтле кеше).

**АДМИНИСТРА'ТОРСКИЙ** — администраторлык...-ы; *административный талант* — администраторлык таланты.

**АДМИНИСТРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — администрация (1. идарә органнары; 2. *собир.* администраторлар, җаваплы башкаручылар).

**АДМИНИСТРИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. администраторлык итү, идарә итү; 2. *неодобр.* түрәлек итү, түрәләрчә кылану (эшнең асылына кермичә, өстән генә идарә итү, коры боерулар белән генә идарә итү).

**АДМИРА'Л** *м.* — адмирал (хәрби диңгез флотында иң югары гаскәри чин).

**АДМИРАЛТЕ'ЙСТВО** *ср.* — адмиралтейство (1. хәрби судноллар ясау һәм җиһазлау урыны; 2. кайбер илләрдә хәрби диңгез көчләренең иң югары идарә органы. 3. Ленинградта элекке хәрби флот баш идарәсенең бинасы).

**АДМИРА'ЛЬСКИЙ** — адмирал...-ы; *адмиральский флаг* — адмирал флагы.

**АДО'НИС** *м. бот.* — адонис, утчәчәк.

**АДОПТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — адоптация, уллыкка алу, кызлыкка алу.

**А'ДРЕС** *м.* — 1. (*мн.* адреса') адрес; *доставить письмо по адресу* — хатны адресы буенча илтеп тапшыру; 2. адрес, котлау язуы (берәр дата, мәсәлән, 60 яшь тулу унае белән хезмәт яки фән эшлеклесенә бирелә торган котлау язуы). ◇ **По адресу кого** — ...-га карата; *по его адресу было сделано несколько замечаний* — аңа карата берничә искәртү ясалган иде. **Не по адресу** — кешесенә карата түгел, тиешле урынына түгел; карамый, кагылмый.

**АДРЕСА'НТ** *м.* — адресант, адреслаучы, хат (посылка) җибәрүче.

**АДРЕСА'Т** *м.* — адресат (җибәрелгән хатны яки посылканы алырга тиеш булган кеше, учреждение).

**А'ДРЕСНЫЙ** — адреслар...-ы; *адресный стол* — адреслар өстәле (зур шәһәрләрдә кемнең кайда торуы турында белешмә бирә торган учреждение).

**АДРЕСОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. адреслау, адрес буенча җибәрү; 2. җибәрү; *этого человека адресовал ко мне старый друг* — бу кешене миңа иске дустым җибәргән.

**АДРЕСОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. *страд.* адреслану, адрес буенча җибәрелү; җибәрелү; 2. *устар. офиц.* мөрәҗәгать итү.

**А'ДСКИ** *нареч.* — бик, үтә, чиктән тыш, җәһәннәмдәй; *адски холодно* — чиктән тыш суык.

**А'ДСКИЙ** — 1. усал, явыз; *адский замысел* — явыз ният, явыз уй; 2. *перен.* бик көчле, түзә алмаслык; *адский холод* — түзә алмаслык салкын, җәһәннәм салкыны. ◇ **Адская машина** — җәһәннәм машинасы (билгеләнгән вакытта шартлый торган снаряд). **Адский камень** — ляпис.

**АДЪЮ'НКТ** *м.* — адъюнкт (1. хәрби академияләрдә укытучы булырга хәзерләнүче аспирант; 2. *устар.* гыйльми учреждениедә кече гыйльми дәрәҗәле кеше).

**АДЪЮТА'НТ** *м.* — адъютант (хәрби начальник карамагында хезмәт йомышларын яки штаб эшләрен үтәүче офицер).

**АДЪЮТА'НТСКИЙ** — адъютант..-ы, адъютантлык...-ы; *адъютантская должность* — адъютантлык вазифасы.

**АДЭКВА'ТНЫЙ** — тәңгәл, тиңдәш, туры (килгән), тапкыр (килгән).

**АЖИОТА'Ж** *м.* — 1. *ком.* ажиотаж (капиталистик илләрдә — спекуляция максаты белән кыйммәтле кәгазь, товар һ. б. бәясен күтәрү яки төшерү); 2. *перен. (сильное волнение)* ярсу, көчле дулкынлану.

**АЖИТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — ярсу, дулкынлану, дәртләнү, ашкыну.

**АЖУ'Р** I *нареч. бухг.* — шул ук вакытта, шул ук минутта язып; *у нас бухгалтерия ведётся ажур* — бездә бухгалтерия исәпләре шул ук вакытта язып барыла.

**АЖУ'Р** II *м. мн.* нет — ажур (челтәрләп эшләнгән юка тукыма).

**АЖУ'РНЫЙ** — 1. *(сквозной, прозрачный)* ажурлы, үтә күренмәле, челтәрле; 2. *перен. (искусно и тонко сделанный)* оста эшләнгән, пөхтә эшләнгән.

**АЗ** *м.* — 1. аз (борынгы рус алфавитында „а" хәрефенең исеме); 2. *только мн. разг.* башлангыч мәгълүматлар, элементар мәгълүматлар. ◇ **Ни аза не знать (не понимать, не смыслить)** — бернәрсә дә белмәү, әлифне таяк дип белмәү.

**АЗА'РТ** *м. мн.* нет — 1. азарт, кызып китү; көчле мавыгу, һәвәсләнү (берәр нәрсә белән иләсләнү, берәр нәрсәгә бирелү); 2. комар (акчалы карта уены); 3. комарлану (уен белән үтә мавыгу).

**АЗА'РТНО** *нареч.* — азарт белән, азартка бирелеп, кызып китеп.

**АЗА'РТНЫЙ** — мавыгучан, тыйнаксыз, кызып китүчән. ◇ **Азартная игра** — комар(лы) уен.

**АЗБЕ'СТ** *м. мин.* — азбест (утка чыдам сүссыман минерал).

**АЗБЕ'СТОВЫЙ** — 1. азбест...-ы; *азбестовые залежи* — азбест ятмалары; 2. азбест..., азбесттан ясалган; *азбестовый шнур* — азбест шнур.

**А'ЗБУКА** *ж.* — 1. алфавит; 2. әлифба (китап); 3. *перен.* башлангыч, әлифба; *азбука науки* — фәннең башлангычы, әлифбасы. ◇ **Азбука Морзе** — Морзе азбукасы (телеграфта кулланыла торган шартлы билгеләр).

**А'ЗБУЧНЫЙ** — 1. әлифба...-ы; *азбучный материал* — әлифба материалы; 2. *перен.* һәркемгә дә билгеле, ачык, гади; *азбучная истина* — һәркемгә дә билгеле хакыйкать.

**АЗЕРБАЙДЖА'НЕЦ** *м.* — азербайҗанлы.

**АЗЕРБАЙДЖА'НКА** *ж.* — азербайҗанлы хатын-кыз.

**АЗЕРБАЙДЖА'НСКИЙ** — азербайҗан ...-ы; азербайджанский язык — азербайҗан теле.

**АЗЕРБАЙЖА'НЦЫ** *мн.* — азербайҗанлылар, Азербайҗан халкы.

**АЗИА'ТСКИЙ** — Азия...-ы; *азиатский материк* — Азия материгы.

**А'ЗИМУТ** *м.* — азимут (1. *астр.* меридиан яссылыгы белән берәр планета аша үтә торган вертикаль яссылыклар арасындагы почмак; 2. *воен.* бирелгән юнәлеш белән төньякка таба булган юнәлеш арасындагы почмак).

**АЗО'ЙСКАЯ Э'РА** — азой эрасы (җирнең геологик тарихында органик тормыш булмаган эра, иң борынгы эра).

**АЗО'Т** *м. мн.* нет — азот (химик элемент; һава составына керә торган төссез газ).

**АЗО'ТИСТЫЙ** — азотлы; *азотистые удобрения* — азотлы ашламалар.

**АЗО'ТНЫЙ** — 1. азот...-ы; *азотная кислота* — азот (нитрат) кислотасы; 2. азотлы; *азотные удобрения* — азотлы ашламалар.

**АЗОТОПОТРЕБИ'ТЕЛИ** *мн. бот.* — азот алучылар (туфрактан азот алучы үсемлекләр).

**АЗОТОСОБИРА'ТЕЛИ** *мн. бот.* — азот җыючылар (туфракны азотка баетучы үсемлекләр).

**АЗЯ'М** *м.* — җилән, чикмән.

**А'ИР** *м. мн.* нет, *бот.* — җир тамыры, кылыч үлән.

**А'ИСТ** *м. зоол.* — ләкләк (кош).

**А'ИСТНИК** *м. бот.* — көтүче инәсе (үсемлек).

**АЙ** *межд.* — 1. әй! абау! (авыртканда, курыкканда әйтелә); 2. әй-әй (шелтә белдергәндә); *ай, как нехорошо* — әй-әй, яхшы түгел! ◇ **Ай да молодец!** — егет тә соң! **Ай-ай-ай!** *межд.* — ай-ай!

**АЙВА'** *ж. мн.* нет — айва (агачы һәм җимеше).

**АЙДА'** *межд. простореч.* — әйдә! (чакыру, өндәү, кыстау).

**А'ЙСБЕРГ** *м.* — айсберг (диңгездә йөзеп йөри торган боз тавы).

**АКАДЕМИ'ЗМ** *м. мн.* нет — академизм (1. фән һәм сәнгать өлкәсендә яшәп килгән традицияләрне саклау; 2. художествода классик (антик) үрнәкләргә иярүнең академик традицияләрен саклаучы, прогрессив һәм яңа агымнарга каршы көрәшүче юнәлеш; 3. фән һәм сәнгать өлкәсендә теориянең практика белән бәйләнмәве; фәннең халыкның иң кирәкле бурычларына бәйләнмәгән булуы, социалистик төзелешнең практик бурычларыннан ерак торуы).

**АКАДЕ'МИК** *м.* — академик (фәннәр академиясе члены).

**АКАДЕМИ'СТ** *м.* — академист (академизмны яклаучы).

**АКАДЕМИ'ЧЕСКИЙ** — 1. академия...-ы; *академический устав* — академия уставы; 2. *(учебный)* академик; *академический час* — академик сәгать (дәрес, лекция өчен билгеләнгән 45—50 минутлык вакыт); 3. *(чисто теоретический)* академик; *академический спор* — академик бәхәс. ◇ **Академическое судно** *спец.* — ярыш судносы. **Академический театр** — Академия театры.

**АКАДЕМИ'ЧНЫЙ** — абстракт, саф теоретик, тормыштан ерак булган.

**АКАДЕ'МИЯ** *ж.* — академия (1. югары гыйльми учреждение; 2. кайбер югары уку йортларының исеме).

**АКА'НТ** *м.* — 1. *бот.* акант, аю йончасы; 2. *арх.* акант (аю йончасы яфракларына охшатып ясалган орнамент).

**А'КАНЬЕ** *ср. мн.* нет — к. акать.

**А'КАТЬ** *несов.* — алаштыру („о“ авазын „а“ авазына тартым итеп әйтү).

**АКА'ЦИЯ** *ж. бот.* — акация, сәрви агачы.

**А'КАЮЩИЙ** — алаштыручы; *акающий говор* — алаштыручы сөйләш.

**АКВАМАРИ'Н** *м.* — аквамарин (яшькелт-күк асылташ).

**АКВАРЕЛИ'СТ** — акварелист (акварель белән рәсем ясаучы художник).

**АКВАРЕ'ЛЬ** *ж.* — акварель (1. суга изелә торган буяу; 2. шундый буяулар белән ясалган рәсем; 3. шундый буяулар белән рәсем ясау).

**АКВАРЕ'ЛЬНЫЙ** — акварель..., акварель белән ясалган; *акварельная краска* — акварель буяу; *акварельный портрет* — акварель белән ясалган портрет.

**АКВА'РИУМ** *м.* — аквариум (балыкларны, су хайваннарын һәм су үсемлекләрен саклау, үрчетү һәм аларның тормышын күзәтү өчен ясалган пыяла савыт яки корылма).

**АКВАТО'РИЯ** *ж.* — акватория (гидросамолётларга очып күтәрелү, төшү һәм хәрәкәт итү өчен билгеләнгән һәм махсус җиһазландырылган су участогы).

**АКВЕДУ'К** *м.* — акведук, сүүткәргеч (тирән чокырлар, үзәннәр яки елгалар аша су үткәрү өчен ясалган күперсыман улак яки көпшә).

**АКВИЛО'Н** *м.* — аквилон, төньяк җиле (төньяк-көнчыгыштан исә торган каты җил).

**АККЛАМА'ЦИЯ** *ж.* — аккламация (нинди дә булса бер тәкъдимне җыелышта тавышка куймыйча кычкырулар юлы белән генә хуплау яки кире кагу).

**АККЛИМАТИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. климатлаштыру, климатка өйрәтү; 2. *перен.* яңа чолганышка җайлаштыру, яңа чолганышка күнектерү.

**АККЛИМАТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. климатлашу, яңа климатка өйрәнү, җайлану; 2. *перен.* яңа чолганышка күнегү, яңа чолганышка ияләшү; 3. *страд.* климатлаштырылу, яңа климатка өйрәтелү.

**АККОМПАНЕМЕ'НТ** *м. мн.* нет — 1. аккомпанемент, кушылып уйнау (җырлаучыга, яки икенче музыка коралында төп көйне яки мелодияне уйнаучыга кушылып уйнау); 2. *перен. разг.* иярчен вакыйгалар, иярчен эшләр (берәр эшкә ияреп бара торган икенче эшләр, вакыйгалар).

**АККОМПАНИА'ТОР** *м.* — аккомпаниатор, кушылып уйнаучы.

**АККОМПАНИ'РОВАТЬ** *несов.* — кушылып уйнау.

**АККО'РД** *м.* — аккорд (төрле авазларның (тоннарның) гармонияле рәвештә кушылып яңгыраулары). ◇ **Заключительный аккорд** *перен.* — соңгы күренеш, соңгы хәл, нәтиҗә.

**АККОРДЕО'Н** *м. муз.* — аккордеон (музыка коралы).

**АККО'РДНЫЙ** — аккорд..., берьюлы түләнә торган, тулаем түләнә торган; *аккордная работа* — аккорд эш, берьюлы түләнә торган эш.

**АККРЕДИТИ'В** *м.*—аккредитив (1. берәүгә акча түләргә кушып бер кредит учреждениесенең икенчесенә җибәргән язуы; 2. чит илгә җибәрелгән вәкилгә бирелә торган ышаныч кәгазе).

**АККРЕДИТИ'ВНАЯ ГРА'МОТА** — аккредитив грамота (дипломатия вәкиленә бирелә торган ышаныч кәгазе).

**АККРЕДИТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*—1. *дипл.* вәкил итеп билгеләү; 2. *фин.* ышаныч бирү, тапшыру (акча алуга, сәүдә эшләре башкаруга).

**АККРЕДИТОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — 1. *дипл.* вәкил итеп билгеләнү; 2. *фин.* ышаныч бирелү, тапшырылу.

**АККУМУЛИ'РОВАТЬ** *несов.* — туплау, җыю.

**АККУМУЛЯ'ТОР** *м.*, *тех.*— аккумулятор (соңыннан файдалану максаты белән электр энергиясен яки җылылыкны туплау приборы).

**АККУМУЛЯ'ТОРНЫЙ** — 1. аккумулятор...-ы; *аккумуляторный ток* — аккумулятор тогы; 2. аккумуляторлы; *аккумуляторная батарея* — аккумуляторлы батарея.

**АККУМУЛЯ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — 1. аккумуляция, туплау, туплану (а. *физ.* энергия туплау, энергия туплану; б. *геол.* диңгез төбендә яки корыда төрле юшкыннарның туплануы); 2. *эк.* туплау, туплану; *аккумуляция капитала* — капитал туплау, капиталның туплануы.

**АККУРА'ТНО** *нареч.* — 1. пөхтә, пөхтә итеп, тәртип белән, төгәллек белән, төгәл, җыйнак, җыйнак итеп; саклык белән, ипләп кенә; 2. *(постоянно)* һәрвакыт, бер дә калдырмый, вакытында, тәртипле; *нам газеты доставляют аккуратно* — безгә газеталарны вакытында китерәләр.

**АККУРА'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — пөхтәлек, җыйнаклык, төгәллек, тәртиплелек.

**АККУРА'ТНЫЙ** — 1. *(исполнительный, исправный)* тыңлаучан, җыйнак, төгәл; 2. *(тщательно сделанный)* пөхтә эшләнгән, җентекләп эшләнгән; 3. *(своевременный)* вакытлы, вакытында; *аккуратная явка на работу* — эшкә вакытында килү.

**АКМЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет — акмеизм (рус әдәбиятында 1912—1913 елларда формалашып, „сәнгать сәнгать өчен" дигән теорияне алга сөреп, индивидуализмга, мистицизмга өндәгән чиктән тыш реакцион-буржуаз агым).

**АКМЕИ'СТ** *м.*— акмеист, акмеизмга нәрүче.

**АКОНИ'Т** *м. бот.* — аконит, аю табаны, аю көпшәсе (агулы үсемлек).

**АКР** *м.* — акр (Англиядә һәм Америкада 4047 кв. метрга тигез булган җир үлчәве).

**АКРИХИ'Н** *м.*— акрихин (маляриягә каршы кулланыла торган дару).

**АКРОБА'Т** *м.* — акробат (гимнастик хәрәкәтләрне башкаручы артист).

**АКРОБАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — акробатизм, акробатлык таланты, акробатлык сәләте.

**АКРОБА'ТИКА** *ж. мн.* нет — акробатика, акробатлык сәнгате.

**АКРОБАТИ'ЧЕСКИЙ** — акробатик...; *акробатические упражнения* — акробатик күнегүләр. ◇ **Приемы его плавания были почти акробатическими**—ул акробатларча диярлек оста йөзә иде.

**АКРО'ПОЛЬ** *м.*— акрополь, ныгытма (борынгы грек шәһәрләрендә).

**АКРОСТИ'Х** *м.* — акростих (юл башындагы хәрефләреннән берәр сүз яки фраза килеп чыгарлык итеп язылган шигырь).

**АКСЕЛЬБА'НТЫ** *мн.* — аксельбантлар (элекке Россиядә һәм кайбер буржуаз армияләрдә штабта хезмәт итә торган офицерларның, адъютантларның, жандармнарның җилкәләре аша үткәрелгән шнурлар).

**АКСЕССУА'Р** *м.* — аксессуар (1. сәхнә җиһазы; 2. рәсемдә төп фигураны тулыландыру өчен ясалган деталь; 3. *перен.* төп күренешкә өстәмә генә булган икенче дәрәҗәдәге күренеш).

**АКСИО'МА** *ж.* — аксиома (дөреслеген исбат итеп торуның кирәге булмаган хакыйкать).

**АКСИОМАТИ'ЧЕСКИЙ** —аксиоматик (исбат итүне сорамый торган).

**АКТ** *м.*— 1. *(действие, поступок)* чыгыш; күренеш, эш, кыланыш, хәрәкәт; *акт безумия* — акылсыз эш (кыланыш); 2. *(документ)* акт; *составить акт* — акт төзү; *приемочный акт* — кабул итеп алу акты; 3. *театр.* пәрдә, бүлек; *трагедия в пяти актах* — биш пәрдәлек (бүлекле) трагедия; 4. *(указ, постановление госуд. значения)* акт; *государственный акт* — дәүләт акты.

**АКТЁР** *м.* — 1. актёр; 2. *перен.* *(притворщик)* юри кыланучы.

**АКТЁРСКИЙ** — актёр...-ы, актёрлар...-ы; *актёрская наружность* — актёр кыяфәте; *актёрский быт* — актёрлар көнкүреше.

**АКТЁРСТВО** *ср. мн.* нет — 1. актёрлык; 2. *перен. разг.* юри кыланучанлык.

**АКТЁРСТВОВАТЬ** *несов. разг.* — 1. актёрлык итү; 2. *перен.* кылану, юри кылану.

**АКТИ'В** I *м.*— актив (партия яки җәмәгать оешмасы членнарының иң алдынгы, эшлекле, политик яктан чыныккан өлеше).

**АКТИ'В** II *м.*— 1. *фин.* актив (предприятиенең барлык мөлкәтенең кыйммәте); 2. *перен.* казаныш, өстенлек, байлык (мәгънәви).

**АКТИВА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — активация (1. активлыкны көчәйтү; 2. *физ.* молекулаларны, атомнарны уяту, хәрәкәткә китерү, тәэсир итү; 3. *физ.* газларны, сыекчаларны сеңдерү сәләтен арттыру өчен агач күмерен һәм башка җисемнәрне махсус эшкәртү).

**АКТИВИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — активлаштыру, активлыгын көчәйтү.

**АКТИВИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. активлашу, активлыгы көчәю; 2. *страд.* активлаштырылу, активлыгы көчәйтелү.

**АКТИВИ'РОВАТЬ** *несов.* — активлаштыру, активлыгын көчәйтү.

**АКТИВИ'СТ** *м.* — активист, оешманың актив члены.

**АКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — активлык; актив эшчәнлек.

**АКТИ'ВНЫЙ** — **1.** актив, эшлекле; *активный член профсоюза* — профсоюзның актив члены; **2.** көчле, тиз; *активная химическая реакция* — көчле химик реакция. ◇ **Активный торговый баланс** — актив сәүдә балансы (илдән чыгарыла торган товарларның анда кертелә торган товарлардан күбрәк булуы).

**А'КТОВЫЙ** — актлар...-ы; *актовая бумага* — актлар кәгазе (договорлар, килешүләр языла торган гербовый кәгазь); *актовые книги* — актлар дәфтәре (нотариусның үз кулыннан үткән актларны яза торган дәфтәре). ◇ **Актовый зал** — актовый зал (тантаналы җыелышлар үткәрелә торган зал).

**АКТРИ'СА** *ж.* — актриса.

**АКТУА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — актуальлек, әһәмиятлелек (бүгенге көн өчен).

**АКТУА'ЛЬНЫЙ** — **1.** актуаль, көнүзәк, зарур, хәзерге көн өчен әһәмиятле; **2.** бар булган, чынбарлыкта булган.

**АКУ'ЛА** *ж.* — **1.** акула, акула балыгы; **2.** *перен.* комсыз (кеше), эксплуататор, ерткыч.

**АКУРА'Т** *нареч. простореч.* — нәкъ, төгәл; *акурат два месяца тому назад* — моннан нәкъ ике ай элек.

**АКУ'СТИКА** *ж. мн.* нет — акустика (**1.** физиканың тавышны өйрәнә торган бүлеге; **2.** биналарда музыканың яки сөйләүнең ишетелүчәнлек шартлары).

**АКУСТИ'ЧЕСКИЙ** — акустик; *акустические условия* — акустик шартлар.

**АКУШЕ'Р, АКУШЁР** *м.* — акушер (йөкле хатыннарга медицина ярдәме күрсәтә торган врач).

**АКУШЕ'РКА** *ж.* — акушерка (йөкле хатыннарга ярдәм күрсәтә торган урта белемле белгеч, врач ярдәмчесе).

**АКУШЕ'РСКИЙ** — акушерлык...-ы; *акушерские курсы* — акушерлык курслары.

**АКУШЕ'РСТВО, АКУШЁРСТВО** *ср. мн.* нет — акушерлык (**1.** медицинаның йөкле хатыннарга ярдәм күрсәтү турындагы бүлеге; **2.** акушер яки акушерка эшчәнлеге).

**АКЦЕ'НТ** *м.* — **1.** *грам., тип.* басым, басым билгесе; **2.** *(произношение)* акцент, әйтелеш (чит тел авазларын яки сүзләрен ана теле законнары тәэсирендә бозып әйтү); **3.** *муз.* ритмик басым. ◇ **Сделать акцент (на чём-л.)** — (берәр нәрсәгә) басым ясау, аеруча әһәмият бирү.

**АКЦЕНТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — **1.** ачык әйтү, дөрес басым белән әйтү; **2.** *перен.* басым ясап әйтү.

**АКЦЕНТУА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — акцентуация (**1.** басымнар куеп чыгу; **2.** сөйләгәндә кирәкле урыннарда тавышны күтәрү).

**АКЦЕ'ПТ** *м.* — акцепт (**1.** вексель, счёт кебекләр буенча акча түләүгә ризалык; **2.** шул ризалыкны белдерү өчен вексельгә язылган язу).

**АКЦЕПТА'НТ** *м.* — акцептант (счёт, вексель кебекләр буенча акча түләүгә ризалык биргән кеше).

**АКЦЕПТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — **1.** акцепт бирү; **2.** *перен.* хуплау.

**АКЦЕПТОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — акцепт бирелү.

**АКЦИДЕ'НТНЫЙ** — очраклы, икенче дәрәҗәдәге, артык әһәмияте булмаган.

**АКЦИДЕ'НЦИЯ** *ж.* — акциденция (очраклылык, предметның очраклы булуы, үзгәрә торган булуы, әһәмиятсез сыйфаты).

**АКЦИ'З** *м. мн.* нет — акциз (капиталистик илләрдә кайбер товарларның сату бәясен арттыру юлы белән салына торган кыек налог).

**АКЦИ'ЗНЫЙ** — акциз...-ы; *акцизный сбор* — акциз җыемы.

**АКЦИОНЕ'Р** *м.* — акционер (акцияләр хуҗасы).

**АКЦИОНЕ'РНЫЙ** — **1.** акцияләр...-ы; *акционерный капитал* — акцияләр капиталы; **2.** акционерлар...-ы; *акционерное общество* — акционерлар җәмгыяте.

**АКЦИОНЕ'РСКИЙ** — акционерлар...-ы; *акционерское собрание* — акционерлар җыелышы.

**А'КЦИЯ** I *ж.* — **1.** *фин.* акция (сәүдә һәм промышленность предприятиеләре тарафыннан чыгарыла торган кыйммәтле кәгазь — пай документы); **2.** *перен. только мн.* дәрәҗә; *его акции сильно поднялись* — аның дәрәҗәсе бик нык күтәрелде.

**А'КЦИЯ** II *ж. дипл.* — акция, эш, хәрәкәт, хәл.

**АКЫ'Н** *м.* — акын (казахларда халык җырчысы, шагыйре).

**АЛБА'НЕЦ** *м.* — албанияле.

**АЛБА'НКА** *ж.* — албанияле хатын-кыз.

**АЛБА'НСКИЙ** — албан...-ы; *албанский язык* — албан теле.

**АЛБА'НЦЫ** *мн.* — албаниялеләр, Албания халкы.

**А'ЛГЕБРА** *ж. мн.* нет — алгебра (математиканың бер бүлеге).

**АЛГЕБРАИ'СТ** *м.* — алгебрачы, алгебра галиме, алгебра белгече.

**АЛГЕБРАИ'ЧЕСКИЙ** — алгебраик; *алгебраическое решение* — алгебраик чишелеш.

**АЛЕБА'СТР** *м. мн.* нет — алебастр.

**АЛЕБА'СТРОВЫЙ** — **1.** алебастр...-ы; *алебастровый завод* — алебастр заводы; **2.** алебастр..., алебастрдан ясалган; *алебастровый бюст* — алебастр бюст.

**А'ЛЕНЬКИЙ** — алсу (төс).

**АЛЕ'ТЬ** *несов.* — **1.** *(становиться алым)* аллану, алсулану, ал төскә керү; **2.** *(виднеться)* алсуланып күренү, алсуланып тору.

**А'ЛИ, АЛЬ** *союз, простореч.* — к. или.

**А'ЛИБИ** *ср. нескл.* — алиби (берәр җинаять ясауда гаепләнүченең гаепсезлегенә дәлил буларак, җинаять ясалган вакытта анда булмавы).

**АЛИЗАРИ'Н** *м.* — ализарин (буяу ясау өчен китә торган матдә).

**АЛИЗАРИ'НОВЫЙ** — ализарин(нан ясалган); *ализариновые краски* — ализарин буяулар.

**АЛИМЕ'НТНЫЙ** — алимент...-ы; *алиментные дела* — алимент эшләре (судта).

**АЛИМЕ'НТЩИК** *м. разг.* — алимент түләүче.

**АЛИМЕ'НТЩИЦА** *ж. разг.* — алимент алып торучы хатын.

**АЛИМЕ'НТЫ** *ед.* нет — алимент.

**АЛКА'ТЬ** *несов.* — көчле теләү, бик нык теләү.

**АЛКОГОЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — алкоголизация (катылыгын көчәйтү өчен виноград аракысына спирт кушу).

**АЛКОГОЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — алкоголизм, эчкечелеккә сабышу.

**АЛКОГО'ЛИК** *м.* — алкоголик, эчкечелеккә сабышкан кеше, эчкече, исерекбаш.

**АЛКОГОЛИ'ЧЕСКИЙ** — алкоголик...-ы; *алкоголические наклонности* — алкоголик гадәтләре.

**АЛКОГО'ЛЬ** *м.* — алкоголь, спирт, аракы.

**АЛКОГО'ЛЬНЫЙ** — алкогольле, спиртлы; *алкогольные напитки* — спиртлы эчемлекләр.

**АЛЛА'Х** *м. мн.* нет — алла. ◇ **Аллах его знает или одному аллаху известно** — алла белсен (билгеле түгел, белмим).

**АЛЛЕГОРИ'ЧЕСКИЙ, АЛЛЕГОРИ'ЧНЫЙ** — аллегорик, кинаяле, читләтеп әйтелгән.

**АЛЛЕГО'РИЯ** *ж.* — **1.** аллегория, киная, читләтеп әйтү (абстракт төшенчәләрне конкрет образлар аша сурәтләп бирү); **2.** кинаялелек, читләтелгән мәгънә; **3.** *только мн.* томанлы, аңлаешсыз сөйләм.

**АЛЛЕ'Я** *ж.* — аллея (ике ягына агачлар утыртылган юл).

**АЛЛИЛУ'ЙЩИК** *м.* — аллилуйчы (житешсезлекләрне яшерергә тырышып, кирәгеннән артык мактаучы).

**АЛЛИЛУ'ЙЩИНА** *ж. мн.* нет — аллилуйчылык (житешсезлекләрне яшерергә тырышып һәм ялагайланып тиешеннән артык мактау).

**АЛЛО'** *межд.* — алло (телефонда сөйләшкәндә „тыңлыйм", „тыңлагыз" мәгънәсендә).

**АЛЛЮВИА'ЛЬНЫЙ** — аллювиаль (агым су белән агып килеп утырган, мәс., ләм, юшкын).

**АЛЛЮ'ВИЙ** *м.* — юшкын, ләм, дуен.

**АЛЛЮ'Р** *м.* — аллюр (атның йөрү яки чабу ысулы, мәсәлән, юырту, атлатып бару, чабып бару).

**АЛМА'З** *м.* — алмаз (асылташ).

**АЛМА'ЗНЫЙ** — **1.** алмаз...-ы; *алмазные сокровища* — алмаз байлыклары; **2.** алмаз..., алмаздан ясалган; *алмазное украшение* — алмаз бизәк.

**АЛОГИ'ЗМ** *м. мн.* нет *книж.* — алогизм, логикасызлык, логикага каршылык.

**АЛОГИ'ЧЕСКИЙ, АЛОГИ'ЧНЫЙ** — логикасыз, логикага каршы, логикага сыймаган.

**АЛО'Й** *м. мн.* нет, *бот.* — к. алоэ.

**АЛО'ЙНЫЙ** — алой...-ы; *алойный лист* — алой яфрагы.

**АЛО'Э** *ср. нескл.* — алой (Африка үсемлеге, бездә — бүлмә гөле).

**АЛТА'РЬ** *м.* — **1.** *церк.* михрап; **2.** *перен.*: **на алтарь...** — ... хакына, өчен; *напряжённый труд в тылу и на фронте, отданный на алтарь Отечества, не прошёл даром* — тылда һәм фронтта Ватан хакына бирелгән киеренке хезмәт әрәмгә китмәде.

**АЛТЕ'Й** *м.*, **АЛТЕ'Я** *ж. бот.* — песи борчагы, мәче борчагы.

**АЛТЫ'Н** *м.* — барнау (борынгы заманда 3 тиенлек бакыр акчаны шулай дип йөрткәннәр).

**АЛТЫ'ННИК** *м. разг. пренебр.* — саран кеше; вак сәүдәгәр, кырык тартмачы.

**АЛФАВИ'Т** *м.* — алфавит (әлифбада хәрефләрнең урнашу тәртибе; әлифбадагы хәрефләрнең җыелмасы).

**АЛФАВИ'ТНЫЙ** — алфавит...-ы; *алфавитный порядок* — алфавит тәртибе.

**АЛХИ'МИК** *м.* — алхимик, алхимия белән шөгыльләнүче.

**АЛХИ'МИЯ** *ж. мн.* нет — алхимия (фәнни химиядән элек булган мистик фән; ул гади металларны кыйммәтле металларга әверелдерү чарасын — „философия ташы"н эзләгән).

**АЛЧБА'** *ж. мн.* нет — көчле теләк.

**А'ЛЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — комсызлык, туемсызлык, ач күзлелек.

**А'ЛЧНЫЙ** — **1.** *(жадный)* комсыз; **2.** *книж. устар. (ненасытный)* туймас, туемсыз, ач; **3.** *поэт. (страстно желающий)* зур дәртле; көчле теләкле.

**А'ЛЧУЩИЙ** *поэт.* — бик нык теләүче.

**А'ЛЫЙ** — ал (төс).

**АЛЬ** — к. али.

**АЛЬБАТРО'С** *м. зоол.* — альбатрос (лавыл кошлары семьялыгыннан).

**АЛЬБИНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *мед.* — альбинизм (тиренең һәм чәчләрнең пигмент житешмәү аркасында булган аклыгы).

**АЛЬБИНО'С** *м.*, **АЛЬБИНО'СКА** *ж. мед.* — альбинизм белән авыручы.

**АЛЬБО'М** — альбом (**1.** рәсемнәр кую, шигырьләр, автографлар язу өчен дәфтәр; **2.** рәсемнәр, күренешләр җыелмасы).

**АЛЬБО'МНЫЙ** — альбом...-ы; *альбомная бумага* — альбом кәгазе.

**АЛЬБУМИ'Н** *м.* — альбумин, аксым.

**АЛЬКО'В** *м.* — **1.** стена куышы (кровать кую өчен); **2.** *перен.* урын-җир, йоклау бүлмәсе.

**АЛЬКО'ВНЫЙ** — **1.** җенси мөнәсәбәтләргә бәйләнешле; *альковные тайны* — җенси мөнәсәбәтләргә бәйләнешле серләр; **2.** *перен.* мәхәббәт...-ы; *альковный роман* — мәхәббәт романы.

**АЛЬМАНА'Х** *м.* — альманах (**1.** төрле авторларның әдәби әсәрләре җыентыгы; **2.** *устар.* төрле мәгълүматларны эченә ала торган календарь).

**АЛЬПИ'ЙСКИЙ** — Альп...-ы; *альпийские горы* — Альп таулары.

**АЛЬПИНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — альпинизм, тау туризмы.

**АЛЬПИНИ'СТ** *м.* — альпинист, тау туристы.

**АЛЬТ** *м. муз.* — альт (**1.** хатын-кызларның яки балаларның калын тавышы (җырлаганда); **2.** скрипкадан зуррак кыллы музыка коралы).

**АЛЬТЕРНАТИ'ВА** *ж.* — альтернатива (икенең берсен сайлап алу).

**АЛЬТЕРНАТИ'ВНЫЙ** — альтернатив; *альтернативное решение* — альтернатив карар.

**АЛЬТЕРНА'ЦИЯ** *ж. лингв.* — альтернация, авазлар чиратлашу (бер нигездән булган сүзләрдә, мәсәлән, аяк — аягы).

**АЛЬТИ'СТ** *м.* — альтист, альтта уйнаучы.

**АЛЬТО'ВЫЙ** *муз.* — альт...-ы; *альтовая партия* — альт партиясе.

**АЛЬТРУИ'ЗМ** *м. мн.* нет — альтруизм (үзенең шәхси интереслары белән хисаплашмыйча, башкаларга яхшылык итәргә тырышу, башкаларга файда китерергә теләү, тырышу).

**АЛЬТРУИ'СТ** *м.*, **АЛЬТРУИ'СТКА** *ж.* — альтруист (кешегә яхшылык итәргә теләүче, тырышучы).

**АЛЬТРУИСТИ'ЧЕСКИЙ, АЛЬТРУИСТИ'ЧНЫЙ** — альтруистик; *альтруистический поступок* — альтруистик эш.

**А'ЛЬФА** *ж.* — альфа (1. грек алфавитында беренче хәреф; 2. *перен.* берәр нәрсәнең башлангычы). ◇ **От альфы до омеги** — башыннан ахырына кадәр.

**АЛЬЯ'НС** *м.* — альянс, союз, берек; берләшмә.

**АЛЮМИ'НИЕВЫЙ** — 1. алюминий...-ы; *алюминиевая руда* — алюминий рудасы; 2. алюминийдан ясалган; *алюминиевая посуда* — алюминийдан ясалган савыт.

**АЛЮМИ'НИЙ** *м. мн.* нет — алюминий (көмешсыман ак җиңел металл).

**АЛЯПОВА'ТЫЙ** — тупас, шыксыз, алама, тупас эшләнгән.

**АМАЗО'НКА** *ж.* — амазонка (1. атта йөрүче хатын-кыз, җайдак хатын-кыз; 2. атка атланып йөргәндә киелә торган хатын-кыз киеме).

**АМАЗО'НКИ** *мн.* — амазонкалар (борынгы грек мифологиясендә — сугышчан хатын-кызлар кабиләсе).

**АМАЛЬГА'МА** *ж.* — амальгама (1. *хим.* нинди дә булса бер металлның терекөмеш белән катнашмасы; 2. *перен.* төрле әйберләр кушылмасы).

**АМАЛЬГАМИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* *хим.* — 1. амальгама ясау (нинди дә булса металлга терекөмеш кушып); 2. амальгамалап аеру (руданы терекөмеш белән катнаштырып, аннан алтын, көмешне аеру).

**А'МБА** *межд. вульг.* — бетте баш, эш харап.

**АМБА'Р** *м.* — амбар.

**АМБА'РГО** *нескл. ср.* — к. эмбарго.

**АМБА'РИЩЕ** *м.* — зур амбар.

**АМБАРИ'ЩЕ** *ср.* — амбар урыны.

**АМБА'РНЫЙ** — 1. амбар...-ы; *амбарная крыса* — амбар күсесе; *амбарная книга* — амбар кенәгәсе, амбар журналы (товарны язу өчен); 2. в *знач. сущ.* амбарчы; амбар сакчысы. ◇ **Амбарные вредители** — амбар корткычлары (бөҗәкләр һәм күсе-тычкан).

**АМБИЦИО'ЗНЫЙ, АМБИЦИО'ННЫЙ** — амбицияле, тәкәббер, горур, һавалы.

**АМБИ'ЦИЯ** *ж.* — 1. амбиция, горурлык; 2. мин-минлек, тәкәбберлек, һавалылык, борын чөю (күтәрү), эрелек; масаю, шапырыну. ◇ **Человек с амбицией** — тәкәббер кеше, горур кеше, һавалы кеше. **Из амбиции** — горурлыктан, тәкәбберлектән. **Вломиться в амбицию** — үпкәләп чәпчеп китү. **Задеть амбицию** — үпкәләтү, абруен төшерү, намусына тию.

**А'МБРА** *ж.* — 1. гамбәр (кашалот дигән хайваннан чыга торган сумаласыман матдә); 2. *перен. книж. (аромат)* хуш ис.

**АМБРАЗУ'РА** *ж.* — амбразура (1. *воен.* хәрби ныгытмаларның стеналарында ату өчен ясалган махсус тишек, уем; 2. *архит.* тәрәзә уемы, ишек урыны (бина төзегәндә)).

**АМБРЕ'** *ср. нескл.* — 1. гамбәрдән ясалган хушбуй, исле май; 2. хуш ис, тәмле ис; 3. *перен. ирон.* әшәке ис.

**АМБРО'ВЫЙ** — гамбәр...-ы; *амбровый запах* — гамбәр исе.

**АМБРО'ЗИЯ, АМВРО'ЗИЯ** *ж.* — амброзия (1. *только ед.* борынгы грек мифологиясендә — аллалар ашы; 2. *устар. поэт.* хуш ис; 3. *перен.* гадәттән тыш тәмле ашамлык).

**АМБУЛАТО'РИЯ** *ж. мед.* — амбулатория (килеп дәваланучы авыруларны дәвалау учреждениесе).

**АМБУЛАТО'РНЫЙ** — амбулатория...-ы; *амбулаторный врач* — амбулатория врачы. ◇ **Амбулаторный больной** — амбулаториягә йөреп дәваланучы авыру.

**АМВО'Н** *м. рел.* — амвон, мөнбәр.

**АМЁБА** *ж. зоол.* — амёба (бер күзәнәкле иң гади тереклек иясе).

**АМЕРИКА'НЕЦ** *м.* — 1. американы; 2. *ирон.* американ, эшкуар, малкуар, эш кыручы.

**АМЕРИКАНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — америкачылык (1. Америка милләтчелеге, Америка империализмы һәм фашизмы, котырган расачылык; 2. *лингв.* инглиз теленең Америкада барлыкка килгән үзенчәлеге; 3. Америка эшкуарларына хас сыйфатлар, гореф-гадәтләр, акчага хиреслек, шәхси максатларга ирешүдә бернинди чаралардан да тартынмау).

**АМЕРИКА'НСКИЙ** — Америка...-ы; *американский материк* — Америка материгы.

**АМЕРИКА'НЦЫ** *мн.* — америкалылар, Америка халкы.

**АМИКОШО'НСТВО** *ср. мн.* нет — амикошонлык, үтә тартынусызлык, үтә тупас дуслык, үтә тупас мөнәсәбәт.

**АМИКОШО'НСТВОВАТЬ** *несов.* — амикошонлык күрсәтү, үтә тартынусызлык күрсәтү, үтә тупас мөнәсәбәттә булу.

**АММИА'К** *м. мн.* нет, *хим.* — аммиак (1. азот белән водород кушылмасы, ачы исле төссез газ; 2. нашатырь спирты).

**АММИА'ЧНЫЙ** *хим.* — 1. аммиаклы; *аммиачная вода* — аммиаклы су (нашатырь спирты); 2. аммиак...-ы; *аммиачный завод* — аммиак заводы.

**АМНИСТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — амнистияләү, амнистиягә кертү, җәзаны кичерү (яки йомшарту), җәзадан котылдыру.

**АМНИСТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— амнистиягә кертелү, җәзасы кичерелү (яки йомшартылу).

**АМНИ'СТИЯ** *ж. полит., юрид.* — амнистия (җинаятьчеләрнең бөтен бер группасының җәзасын кичерү яки җиңеләйтү; гомумән кичерү, гафу итү).

**АМОРАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — аморальлек, моральсезлек, әхлаксызлык.

**АМОРА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — аморальлек, моральсезлек; әхлаксызлык.

**АМОРА'ЛЬНЫЙ** — 1. амораль, моральсез (әхлак нормалары белән исәпләшмәүче); 2. әхлаксыз, бозык; *аморальный человек*— әхлаксыз кеше.

**АМОРТИЗА'ТОР** *м. техн.*— амортизатор, йомшарткыч (автомобильләрдә, самолётларда бәрелү-сугылу тәэсирен йомшарткыч).

**АМОРТИЗАЦИО'ННЫЙ** — 1. *эк.* амортизация...-ы; *амортизационный срок* — амортизация срогы; 2. амортизацион; *амортизационный капитал* — амортизацион капитал.

**АМОРТИЗА'ЦИЯ** *ж.*—амортизация (1. *эк.* тузу сәбәпле милекнең бәясе кими бару; 2. *фин.* бурычны каплау; 3. *тех.* автомобильләрнең барганда, самолётларның җиргә төшкәндә бәрелүләрен йомшарту; 4. документның көчен туктату, аны яраксыз дип тану).

**АМОРТИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*—амортизацияләү, амортизация ясау.

**АМОРТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — амортизацияләнү, амортизация ясалу.

**АМОРТИФИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — амортификация (гамәлдән чыккан хокукларның яки документларның бетерелүе турында рәсми белдерү).

**АМОРФИ'ЗМ** *м. мн.* нет, **АМО'РФНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *биол.* — аморфлык, формасызлык.

**АМО'РФНЫЙ** — 1. аморф; *аморфное состояние* — аморф хәл; 2. *перен. книж.* формасыз, таркау.

**АМПЕ'Р** *м. физ.* — ампер (электр тогы зурлыгын үлчәү берәмлеге).

**АМПЕРМЕ'ТР** *м. физ. тех.* — амперметр (электр тогы зурлыгын үлчи торган прибор).

**АМПИ'Р** *м. мн.* нет — ампир (XIX йөз башында Франциядә килеп чыккан сәнгать стиле).

**АМПЛИТУ'ДА** *ж. физ.* — 1. амплитуда (а. тибрәнү киңлеге, мәсәлән, сәгать теленең; б. барометрның яки термометрның биеклекләре аермасы; в. снарядның очу ераклыгы); 2. *перен.* колач, киңлек.

**АМПЛИФИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — амплификация (стилистикада — күренешләрнең характеристикасын көчәйтү өчен берничә охшаш аергычның бергә тупланулы, мәсәлән, „ул батыр, йөрәкле, гайрәтле кеше").

**АМПЛУА'** *ср. нескл.*— 1. амплуа (артист башкара торган рольләрнең характеры); 2. *перен.* роль (җәмгыятьтә тоткан урын).

**А'МПУЛА** *ж. мед.*— ампула (дару саклау өчен кулланыла торган тар муенлы пыяла савыт).

**АМПУТАЦИО'ННЫЙ** *мед.* — 1. ампутация...-ы; *ампутационный нож* — ампутация пычагы; 2. ампутация ясалырга тиешле; *ампутационный больной* — ампутация ясалырга тиешле авыру.

**АМПУТА'ЦИЯ** *ж. мед.*— ампутация, кисеп алу (операция юлы белән аякның яки кулның берәр өлешен).

**АМПУТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— ампутацияләү, ампутация ясау, кисеп алу (операция юлы белән).

**АМПУТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— ампутацияләнү, ампутация ясалу, кисеп алыну.

**АМУЛЕ'Т** *м.*— бөти.

**АМУНИ'ЦИЯ** *ж.* — амуниция (солдатның коралдан һәм кием-салымнан башка кирәк-яраклары). ◇ **Конская амуниция** — ат җигү кирәк-яраклары.

**АМУ'Р** *м.*— 1 амур (борынгы грек мифологиясендә — мәхәббәт алласы). 2. *устар.* мәхәббәт, сөю; 3. *только мн.* мәхәббәт эшләре; *заниматься амурами* — мәхәббәт эшләре белән шөгыльләнү.

**АМУ'РИТЬСЯ, АМУ'РНИЧАТЬ** *несов. разг. шутл.*— мәхәббәт сату.

**АМУ'РНЫЙ** *простореч.* — мәхәббәт...-ы; сөю...-ы; *амурные письма* — мәхәббәт хатлары.

**АМФИ'БИЯ** *ж.*— амфибия (1. *зоол.* җирсу хайваны; 2. *бот.* җир-су үсемлеге; 3. *ав.* җиргә дә, суга да төшә һәм шуларның икесеннән дә күтәрелеп китә ала торган самолёт; җирдә дә, суда да йөри ала торган танк).

**АМФИБРА'ХИЙ** *м.* — амфибрахий (өч иҗекле, уртадагы иҗеге басымлы шигырь үлчәве).

**АМФИБРАХИ'ЧЕСКИЙ** — амфибрахик; амфибрахийлы; *амфибрахический размер*— амфибрахик үлчәү; *амфибрахический стих* — амфибрахийлы тезмә.

**АМФИТЕА'ТР** *м.*— амфитеатр (1. борынгы грекларда һәм римлыларда — цирксыман тамаша урыны; 2. хәзерге театрларда һәм циркларда — партер артындагы яки ложалар өстендәге югарыгы ярым түгәрәк урыннар).

**АН** — *союз противительн. простореч.*— ләкин, әмма, чынлыкта исә.

**АНАГРА'ММА** *ж.* — анаграмма (хәрефләрнең урынын алмаштырып бер сүздән икенче сүз ясау, мәс., кит — тик).

**АНАКРЕОНТИ'ЧЕСКИЙ** — анакреонтик; *анакреонтическая поэзия* — анакреонтик поэзия (мәхәббәт, аракы һ. б. турында язылган поэзия).

**АНА'ЛИЗ** *м.*— анализ (1. предметны яки күренешне аерым кисәкләргә бүлеп өйрәнү методы; 2. нинди дә булса берәр матдәне аерым элементларга таркату, аларны тикшерү; *химический анализ* — химик анализ; 3. бөтен турында хөкем йөртү өчен предметның аерым кисәкләрен тикшерү; *грамматический анализ* — грамматик анализ).

**АНАЛИЗИ'РОВАТЬ** *несов.* — анализлау, анализ ясау, һәрьяклап өйрәнү, һәрьяклап тикшерү.

**АНАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— анализлану, анализ ясалу, һәрьяклап өйрәнелү (тикшерелү).

**АНАЛИ'ТИК** *м.* — аналитик, анализчы (тикшергәндә анализ методлары белән эш итүче).

**АНАЛИ'ТИКО-СИНТЕТИ'ЧЕСКИЙ МЕ'ТОД** — анализ-синтез методы, аналитик-синтетик метод (балаларны укырга-язарга өйрәтү методы).

**АНАЛИТИ'ЧЕСКИЙ** — аналитик, анализ...-ы; *аналитический метод* — аналитик метод, анализ методы.

**АНА'ЛОГ** *м.* — аналог (берәр нәрсәнең яки күренешнең охшашы).

**АНАЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — аналогик, аналогиягә нигезләнгән.

**АНАЛОГИ'ЧНЫЙ** — аналогик, охшаш, шундый ук; *аналогичное явление* — шундый ук күренеш.

**АНАЛО'ГИЯ** *ж.* — аналогия, охшашлык (гомумән төрле күренешләрнең яки предметларның берәр яктан охшашлыгы).

**АНАНА'С** *м. бот.* — ананас (агачы һәм җимеше).

**АНАНА'СНЫЙ, АНАНА'СОВЫЙ** — ананас...-ы; *ананасовое варенье* — ананас вареньесы.

**АНА'ПЕСТ** *м.*— анапест (өч иҗекле, өченче иҗеге басымлы шигырь үлчәве).

**АНАРХИ'ЗМ** *м. мн.* нет — 1. анархизм (марксизмга дошман булган һәм анархияне яклаучы вак буржуаз политик агым); 2. властьны, авторитетны танымау, башбаштаклык.

**АНАРХИ'СТ** *м.*— анархист (1. анархизмны яклаучы; анархистлар оешмасының члены; 2. властька, авторитетка буйсынмаучы, башбаштак кеше).

**АНАРХИ'СТСКИЙ** — 1. анархистларча...; *анархистский взгляд* — анархистларча караш; 2. анархистлар...-ы; *анархистская группа* — анархистлар группасы.

**АНАРХИ'ЧЕСКИЙ** — анархизм...-ы, анархия...-ы, анархик; *анархические идеи* — анархизм идеяләре; *анархические явления*— анархия күренешләре; *анархическое хозяйство* — анархик хуҗалык.

**АНАРХИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәртипсезлек, башбаштаклык.

**АНАРХИ'ЧНЫЙ** — тәртипсез, дисциплинасыз, башбаштак.

**АНА'РХИЯ** *ж. мн.* нет — 1. анархия, властьсызлык; 2. тәртипсезлек, башбаштаклык.

**АНА'ТОМ** *м. мед.* — анатом, анатомия белгече, анатомия галиме.

**АНАТОМИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. мед.*— яру (мәет турында).

**АНАТОМИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. мед.*— ярылу (мәет турында).

**АНАТОМИ'ЧЕСКИЙ** — анатомик, анатомия...-ы; *анатомический атлас* — анатомия атласы; *анатомический театр* — анатомик театр (мәетләрне яру бинасы).

**АНАТОМИ'ЧКА** *ж.*— анатомичка (мәетләрне яру бинасы).

**АНАТО'МИЯ** *ж. мн.* нет — анатомия (кешеләрнең, хайваннарның, үсемлекләрнең эчке төзелешләре турындагы фән).

**АНА'ФЕМА** *ж.* — 1. *церк.* диннән сөрү; 2. *просторец. бран.* ләгънәт; мәлгунь, ләгънәт төшкән нәрсә.

**АНАФЕМА'ТСТВОВАТЬ** *несов.* — диннән сөрү; каргау.

**АНА'ФЕМСКИЙ** — 1. кабахәт, әшәке, ләгънәт төшкән; *анафемский поступок* — кабахәт эш; *анафемская работа* — ләгънәт төшкән эш; 2. *перен.* каты, җәһәннәм...-ы; *анафемский холод* — каты суык, җәһәннәм суыгы.

**АНА'ФОРА** *ж.*— анафора (сөйләмнең ике яки берничә кисәкләре башында бер үк сүзнең яки авазның кабатлануыннан гыйбарәт булган поэтик алым. Мәсәлән:

> Нигә шауламасын бөтен шәһәр,
> Нигә шатланмасын авыллар?
> Нигә ташымасын ташкын сулар,
> Нигә җанланмасын басулар.
>
> *(М. Гафури).*

**АНАХОРЕ'Т** *м. книж. устар.*— дәрвиш, ялгызлыкта яшәүче.

**АНАХРОНИ'ЗМ** *м.*— анахронизм (1. хронологияне саташтыру, тарихи вакыйгаларны икенче заманга күчереп күрсәтү; 2. хәзерге шартларга туры килми торган, искергән күренеш яки төшенчә).

**АНАХРОНИ'ЧЕСКИЙ** — анахроник.

**АНГАЖЕМЕ'НТ** *м.*— ангажемент (билгеле срокка яки билгеле санда спектакльдә катнашу өчен артист белән төзелгән договор).

**АНГАЖИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— артист белән контракт төзү; чакыру.

**АНГАЖИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. ангажемент кабул итү; 2. *разг. фам.* күп вәгъдәләр бирү; 3. *страд.* артист белән контракт төзелү; чакырылу.

**АНГА'Р** *м.*— ангар (самолётлар саклана торган корылма).

**АНГА'РНЫЙ** — ангар...; *ангарное имущество* — ангар милке.

**А'НГЕЛ** *м.* — 1. *рел.* фәрештә; 2. *перен.* сөекле; *ангел мой* — сөеклем.

**АНГИ'НА** *ж. мед.* — ангина, тамак бакасы.

**АНГИ'ННЫЙ, АНГИНО'ЗНЫЙ** — ангина...-ы; *ангинная инфекция* — ангина инфекциясе.

**АНГЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. устар.*— инглизләштерү, инглизләрчә ясау.

**АНГЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. устар.*—инглизләштерелү, инглизләрчә ясалу.

**АНГЛИ'ЙСКИЙ**—инглиз...-ы; Англия...-ы; *английский язык* — инглиз теле; *английский флот* — Англия флоты. ◇ **Английская болезнь** — рахит (авыруы).

**АНГЛИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет — инглизчәлек (инглиз теленнән алынган сүз яки сөйләм әйләнмәсе).

**АНГЛИЧА'НЕ** *мн.* — инглизләр, англичаннар, инглиз халкы.

**АНГЛИЧА'НИН** *м.*— инглиз, англияле.

**АНГЛИЧА'НКА** *ж.*— инглиз хатын-кызы, англияле хатын-кыз.

**АНГЛО-АМЕРИКА'НСКИЙ** — Англия-Америка...-ы; *англо-американский блок* — Англия-Америка блогы.

**АНГЛО-САКСО'НСКИЙ** — инглиз-саксон...-ы; *англо-саксонский язык* — инглиз-саксон теле.

**АНГЛОМА'Н** *м.*— англоман (гореф-гадәттә, тормышта инглизләргә иярүче, Англиядә эшләнгән барлык әйберләрне сөюче).

**АНГЛОМА'НИЯ** *ж. мн.* нет, **АНГЛОМА'НСТВО** *ср. мн.* нет —англомания, англоманлык (гореф-гадәттә, тормышта инглизләрчә булырга тырышу, Англиядә эшләнгән барлык әйберне сөю).

**АНГЛОМА'НСКИЙ**—англоман...-ы; *англоманские взгляды* — англоман карашлары.

**АНГЛОФИ'Л** *м.*— англофил (инглиз милләтен һәм культурасын яклаучы һәм яратучы).

**АНГЛОФИ'ЛЬСКИЙ** — англофил...-ы; *англофильские взгляды* — англофил карашлары.

**АНГЛОФИ'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — англофиллык.

**АНГЛОФО'Б** *м.*— англофоб (инглиз милләтенең һәм культурасының дошманы, аларга нәфрәт белән караучы).

**АНГЛОФО'БСКИЙ**—англофоб...-ы; *англофобские взгляды* — англофоб карашлары.

**АНГЛОФО'БСТВО** *ср. мн.* нет — англофоблык.

**АНГОФРАЗИ'Я** *ж. мн.* нет — ангофразия (сөйләгәндә кирәкмәгәнгә а-а, э-э кебек сузык авазлар кертеп сөйләүдән гыйбарәт житешсезлек).

**АНЕКДО'Т** *м.* —анеклот (1. кызыклы, көлке вакыйга турында кыска хикәя; 2. *перен.* кеше ышанмаслык вакыйга, уйдырма).

**АНЕКДОТИ'СТ** *м.*— анекдотчы, анекдотлар сөйләүче.

**АНЕКДОТИ'ЧЕСКИЙ, АНЕКДОТИ'ЧНЫЙ** — анекдотка охшаган, кеше ышанмаслык, мәзәк.

**АНЕМИ'ЧЕСКИЙ, АНЕМИ'ЧНЫЙ — 1.** аз канлы; **2.** *перен.* зәгыйфь, сүлпән.

**АНЕМИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — анемия, кан азлык.

**АНЕМО'Н** *м.*, **АНЕМО'НА** *ж. бот.*— анемона, жилдәк, умырзая.

**АНЕСТЕЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. мед.*— анестезияләү, авырту сизүне бетерү.

**АНЕСТЕЗИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.*— анестезия, сизмәүчәнлек (авыртуны сизү тойгысын югалту).

**АНИЛИ'Н** *м. хим.*— анилин (буяу хәзерләгәндә кулланыла торган төссез сыекча).

**АНИЛИ'НОВЫЙ — 1.** анилин...-ы; *анилиновый завод* — анилин заводы; **2.** анилинлы; *анилиновая соль* — анилинлы тоз.

**АНИМАЛИ'СТ** *м.*—анималист (хайваннар рәсемен төшерүче художник).

**АНИМИ'ЗМ** *м. мн.* нет — анимизм (һәр нәрсәнең җаны бар дип тану; борынгылар фикеренчә табигать көчләрен һәм күренешләрен җанлы дип санау).

**АНИМИСТИ'ЧЕСКИЙ** — анимистик; *анимистические воззрения* — анимистик карашлар.

**АНИ'С** *м. мн.* нет, *бот.*— әнис (1. үсемлек һәм аның орлыгы; 2. алма төре).

**АНИ'СОВКА** *ж. мн.* нет — 1. әнис алма; 2. әнис аракысы.

**АНИ'СОВЫЙ — 1.** әнис...-ы; *анисовые капли* — әнис тамчылары; **2.** әнистә төнәтелгән; *анисовая водка* — әнистә төнәтелгән аракы.

**А'НКЕР** *м.*— анкер (1. сәгать теленең регуляторы; 2. таштан, кирпечтән биналар салганда ташларны бер-берсенә беркетү өчен кулланыла торган атлама, ныгыткыч).

**АНКЕ'ТА** *ж.*— анкета.

**АНКЕ'ТНЫЙ** — анкета...-ы; *анкетные данные* — анкета мәгълүматлары.

**АНКИЛОСТО'МА** *ж. мед.*— анкилостома (кешенең һәм хайваннарның нәзек эчәкләрендә була торган паразит корт).

**АННАЛИ'СТ** *м.*— елъязмачы.

**АННА'ЛЫ** *ед.* нет — **1.** *(летопись)* елъязмалар; **2.** анналлар (фәнни журналлар исеме).

**АННЕКСИОНИ'СТ** *м. полит.* — аннексионист, басып алучы, аннексияләүче.

**АННЕКСИОНИ'СТСКИЙ** *полит.*— аннексионистик, аннексия...-ы; басып алу...-ы; *аннексионистская политика* — аннексионистик политика, аннексия политикасы, басып алу политикасы.

**АННЕКСИО'ННЫЙ** *полит.* — аннексион, аннексия...-ы; *аннексионная политика* — аннексия политикасы.

**АННЕКСИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. полит.*— аннексияләү (берәр илне яки аның берәр өлешен көчләп басып алу).

**АННЕКСИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. полит.*— аннексияләнү, басып алыну.

**АННЕ'КСИЯ** *ж. полит.* — аннексия (бер дәүләтнең икенче дәүләт жирен басып алуы).

**АННЕКТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — к. аннексировать.

**АННОТА'ЦИЯ** *ж.*— аннотация (китапның яки мәкаләнең эчтәлегенә карата кыскача характеристика).

**АННОТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — аннотацияләү, аннотация язу.

**АННОТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.*— аннотацияләнү, аннотация язылу.

**АННУЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — юкка чыгару, бетерү, көченнән чыгару, гамәлдән чыгару (берәр законны, карарны).

**АННУЛИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— юкка чыгарылу, көченнән чыгарылу, гамәлдән чыгарылу (закон, карар турында).

**АННУЛЯ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — аннуляция (берәр актны, договорны яки хокукны бетерү, гамәлдән чыккан дип игълан итү).

**АНО'Д** *м. физ.* — анод, уңай электрод.

**АНОМАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *астр.* — аномалистик; *аномалистический месяц* — аномалистик ай (27,5 тәүлек чамасы); *аномалистический год* — аномалистик ел (365,26 тәүлек чамасы).

**АНОМА'ЛИЯ** *ж.* — аномалия (нормадан авышу).

**АНО'НИМ** *м.*— аноним (1. әсәрендә, хатында үзенең исемен яшергән автор; 2. авторның исеме яшерелгән әсәр).

**АНОНИ'МКА** *ж.* — анонимка, имзасыз (язучысы билгесез) хат.

**АНОНИ'МНЫЙ** — имзасыз (авторның имзасы куелмаган).

**АНО'НС** *м.*— анонс (алдан ясалган кыскача игълан, белдерү).

**АНОНСИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— алдан белдерү, игълан итү.

**АНОНСИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— алдан белдерелү.

**АНОНСОДА'ТЕЛЬ** *м.* — анонс бирүче (вакытлы матбугатка игълан бирүче).

**АНОРМА'ЛЬНЫЙ** — анормаль, нормаль булмаган.

**АНО'ФЕЛЕС** *м. зоол.* — анофелес, малярия озынборыны.

**АНСА'МБЛЬ** *м.* — ансамбль (1. бер бөтеннең төрле кисәкләре арасында үзара ярашканлык, берләшкәнлек; 2. *театр.* спектакльне башкаручыларның составы; 3. музыкаль әсәрне башкаруда берничә кешенең бергәләп катнашуы).

**АНТАГОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — антагонизм (килешә алмаслык каршылык, мәсәлән, сыйнфый каршылык).

**АНТАГОНИ'СТ** *м.* — 1. антагонист, дошман; каршы кеше. 2. *анат.* (бер мускулга каршы хәрәкәт итүче икенче мускул).

**АНТАГОНИСТИ'ЧЕСКИЙ** — антагонистик, килешә алмаслык, дошман...; *антагонистические классы* — антагонистик сыйныфлар, дошман сыйныфлар.

**АНТА'НТА** *ж. мн.* нет, *истор.*— Антанта (империалистик дәүләтләр арасында төзелгән күп кенә килешүләрнең һәм блокларның исеме).

**АНТАРКТИ'ДА** *ж. мн.* нет — Антарктида (Көньяк полюс әйләнәсендәге материк).

**АНТА'РКТИКА** *ж. мн.* нет — Антарктика (җир шарының Көньяк поляр түгәрәге аръягындагы өлеше).

**АНТАРКТИ'ЧЕСКИЙ** — антарктик, Антарктика...-ы; *антарктический материк* — антарктик материк; *антарктическая экспедиция* — Антарктика экспедициясе.

**АНТЕ'ННА** *ж.*— антенна (радио дулкыннарын тотып алу өчен колгаларга эленә торган металл чыбыклар системасы).

**АНТЕ'ННЫЙ** — антенна...-ы; *антенные мачты* — антенна колгалары.

**А'НТИ-** — каршылыкны яки дошманлыкны белдерү өчен күп кенә исемнәргә һәм сыйфатларга ялгана торган алкушымча; татарча „каршы" сүзенә туры килә, мәсәлән, *антиалкогольный* — алкогольгә каршы.

**АНТИАЛКОГО'ЛЬНЫЙ** — алкогольгә каршы.

**АНТИВОЕ'ННЫЙ** — сугышка каршы.

**АНТИГА'ЗЫ** *хим.* — антигазлар (агулы газларның тәэсирен бетерү һәм алардан саклану чаралары).

**АНТИГИГИЕНИ'ЧНЫЙ** — антигигиеник, гигиенага каршы.

**АНТИГОСУДА'РСТВЕННЫЙ** — дәүләткә каршы; *антигосударственный поступок*— дәүләткә каршы эш.

**АНТИДАТИ'РОВАТЬ** *несов.*— узган дата белән документ бирү.

**АНТИДЕМОКРАТИ'ЧЕСКИЙ** — антидемократик, демократиягә каршы; *антидемократические законы* — антидемократик законнар, демократиягә каршы законнар.

**АНТИДИАЛЕКТИ'ЧЕСКИЙ** — антидиалектик, диалектикага каршы; *антидиалектический метод* — антидиалектик метод, диалектикага каршы метод.

**АНТИИМПЕРИАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** — антиимпериалистик, империализмга каршы; *антиимпериалистическое движение* — антиимпериалистик хәрәкәт, империализмга каршы хәрәкәт.

**АНТИИНТЕЛЛЕКТУАЛИ'ЗМ** *м.* — антиинтеллектуализм (хакыйкатьне акыл ярдәме белән танып-белү мөмкинлеген инкарь итү; реакцион идеалистик философиягә хас).

**АНТИИСТОРИ'ЧЕСКИЙ** — тарихка каршы, тарихны бозу...-ы; *антиисторические факты* — тарихны бозу фактлары.

**АНТИКВА'Р(ИЙ)** *м.*— антиквар (борынгы әйберләр, китаплар белән сәүдә итүче, борынгы әйберләр һәвәскәре).

**АНТИКВА'РНЫЙ** — 1. антиквар...-ы; борынгы һәм кыйммәтле; *антикварная вещь* — антиквар (борынгы) әйбер; 2. антиквар...-ы; борынгы кыйммәтле әйберләр белән сәүдә итә торган; *антикварный магазин* — антиквар магазины.

**АНТИКЛЕРИКАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — антиклерикализм (клерикализмга, ягъни чиркәүгә һәм руханиларга каршы юнәлдерелгән, ләкин диннең үзенә каршы булмаган хәрәкәт).

**АНТИКОММУНИСТИ'ЧЕСКИЙ** — антикоммунистик, коммунизмга каршы.

**АНТИКРИ'ТИКА** *ж. мн.* нет — антикритика, тәнкыйтькә каршы тәнкыйть.

**АНТИЛЕ'НИНСКИЙ** — ленинизмга каршы.

**АНТИЛО'ПА** *ж. зоол.*— антилопа (болан токымыннан пар тояклы күшәүче хайван).

**АНТИМАРКСИ'СТСКИЙ** — антимарксистик, марксизмга каршы.

**АНТИМАТЕРИАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** —антиматериалистик, материализмга каршы.

**АНТИМИЛИТАРИ'ЗМ** *м. мн.* нет — антимилитаризм, милитаризмга каршылык.

**АНТИМИЛИТАРИСТИ'ЧЕСКИЙ** — антимилитаристик, милитаризмга каршы; *антимилитаристическое движение* —антимилитаристик хәрәкәт, милитаризмга каршы хәрәкәт.

**АНТИМОНАРХИ'ЧЕСКИЙ** — монархиягә каршы; *антимонархический лозунг* — монархиягә каршы лозунг.

**АНТИМО'НИЙ** *м. мн.* нет, *хим.*— сөрмә.

**АНТИМО'НИЯ** *ж. мн.* нет: **разводить антимонию** — юк-барны сөйләү, суган сату.

**АНТИМОРА'ЛЬНЫЙ** — әхлакка каршы, әдәпкә каршы, әхлаксыз, әдәпсез.

**АНТИНАРО'ДНЫЙ** — халыкка каршы.

**АНТИНАУ'ЧНЫЙ** — фәнгә каршы.

**АНТИНОМИ'ЧЕСКИЙ, АНТИНОМИ'ЧНЫЙ** *филос.* — антиномик (антиномияне үз эченә алучы).

**АНТИНО'МИЯ** *ж. филос.* — антиномия (һәр икесе дә дөрес дип танылган ике положение арасындагы каршылык).

**АНТИОБЩЕ'СТВЕННИК** *м.* — җәмәгатьчелеккә дошман кеше, җәмгыятькә зарар китерүче кеше.

**АНТИОБЩЕ'СТВЕННЫЙ** — җәмәгатьчелеккә каршы, җәмгыятькә зарарлы.

**АНТИПАРТИ'ЙНЫЙ** — партиягә каршы.

**АНТИПАТИ'ЧНЫЙ** — антипатик, сөйкемсез, мәхәббәтсез.

**АНТИПА'ТИЯ** *ж. мн.* нет — антипатия, сөймәү (яратмау) тойгысы.

**АНТИПО'Д** *м.* — 1. *только мн.* антиподлар (җир шарының бер-беренә капма-каршы ике ягында яшәүчеләр); 2. антипод (характеры яки фикере белән башка берәүгә каршы кеше).

**АНТИПРОЛЕТА'РСКИЙ** — пролетариатка каршы.

**АНТИРАБИ'ЧЕСКАЯ ПРИВИ'ВКА** *мед.* — антирабик прививка (котыруга каршы ясала торган прививка).

**АНТИРАБО'ЧИЙ** — эшчеләргә каршы; *антирабочий закон* — эшчеләргә каршы закон.

**АНТИРЕЛИГИО'ЗНИК** *м.*, **АНТИРЕЛИГИОЗНИЦА** *ж.* — дингә каршы көрәшүче.

**АНТИРЕЛИГИО'ЗНЫЙ** — дингә каршы.

**АНТИСАНИТА'РНЫЙ** — санитариягә каршы, санитария кагыйдәләрен бозучы.

**АНТИСЕМИ'Т** *м.* — антисемит, еврейларны дошман күрүче.

**АНТИСЕМИТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — антисемитизм (еврейларны дошман күрү).

**АНТИСЕМИТИ'ЧЕСКИЙ, АНТИСЕМИ'ТСКИЙ** — антисемитларча...; еврейларга каршы; *антисемитская выходка* — еврейларга каршы чыгыш.

**АНТИСОВЕ'ТСКИЙ** — советка каршы.

**АНТИСОЦИА'ЛЬНЫЙ** — җәмгыятькә каршы.

**АНТИТЕ'ЗА** *ж.* — антитеза (1. стилистикада — тойгыларны көчәйтү өчен капма-каршы фикерләрне яки образларны бер-беренә каршы кую; 2. *филос.* капма-каршылык, каршы кую).

**АНТИТЕ'ЗИС** *м.* — антитезис (1. тезиска куелган фикергә каршы фикер; 2. үсеш процессында төп чыганакны танымау, инкарь итү).

**АНТИТЕТИ'ЧЕСКИЙ** — антитетик, каршы; *антитетическое утверждение* — антитетик фикер, каршы фикер.

**АНТИТОКСИ'НЫ** *мн. мед.* — антитоксиннар (токсин тәэсирендә организм тарафыннан эшләп чыгарыла һәм организмны токсин белән агуланудан саклый торган матдәләр).

**АНТИФАШИ'СТ** *м.* — антифашист, фашизм дошманы.

**АНТИФАШИ'СТСКИЙ** — фашизмга каршы; *антифашистское движение* — фашизмга каршы хәрәкәт.

**АНТИ'ХРИСТ** *м.* — 1. *церк.* дәҗҗал (дини); 2. *бран.* динсез, кафер, мөртәт.

**АНТИХУДО'ЖЕСТВЕННЫЙ** — художестволы булмаган, художество кагыйдәләренә каршы.

**АНТИЦИПА'ЦИЯ** *ж.* — антиципация (1. *психол.* берәр буласы ситуациягә яки күренешкә әзер булу, әзерлек күрү, ярашу, мәсәлән, физкультурникның тиешле сигнал булгач, йөгереп китәргә әзер булуы; 2. *филос.* абстракт логик фикер йөртүләргә нигезләнгән һәм практика белән тәҗрибәне танымый торган идеалистик караш; булган тәҗрибәгә таянып, берәр вакыйганың яки күренешнең буласын алдан әйтү, алдан белеп тору).

**АНТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. антиклык (грек-рим дөньясы, аның культурасы); 2. матурлык (йөз, бит турында).

**АНТИ'ЧНЫЙ** — 1. антик (борынгы грек-рим культурасына караган); 2. дөрес төзелешле, матур (йөз, бит турында).

**АНТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — антологик (борынгы грек лирикасы рухында язылган); *антологическая поэзия* — антологик поэзия.

**АНТОЛО'ГИЯ** *ж.* — антология (төрле авторларның кыска әсәрләре һәм шигырьләре җыентыгы).

**АНТО'НИМЫ** *мн.* (*ед.* антоним) — антонимнар (капма-каршы мәгънәле сүзләр, мәсәлән, калын — нечкә).

**АНТО'НОВКА** *ж.* — антоновка (алма төре).

**АНТО'НОВ ОГО'НЬ** *мед.* — гангрена (тәннең нинди дә булса бер өлешенең үлек хәлгә килүе).

**АНТРА'КТ** *м.* — антракт (1. спектакль, концерт бүлекләре арасындагы тәнәфес; 2. пьесаның ике акты арасында уйнала торган кыска музыкаль әсәр).

**АНТРАЦИ'Т** *м. мн.* нет — антрацит (таш күмернең иң яхшы төре).

**АНТРАЦИ'ТНЫЙ, АНТРАЦИ'ТОВЫЙ** — 1. антрацит...-ы; *антрацитные месторождения* — антрацит чыганаклары; 2. антрацит ягыла торган; *антрацитовая печь* — антрацит ягыла торган мич.

**АНТРЕКО'Т** *м.* — антрекот (1. сыерның кабырга ите; 2. кыздырып пешерелгән сыер ите).

**АНТРЕПРЕНЁР** *м. театр.* — антрепренёр (капиталистик илләрдә театр, цирк тотучы).

**АНТРЕПРИ'ЗА** *ж.* — антреприза (капиталистик илләрдә театр, цирк кебек предприятиеләрнең хосусый хуҗа кулында булуы).

**АНТРЕСО'ЛИ** *мн.* (*ед.* антресоль) — антресоль (өйнең өске тәбәнәк этажы).

**АНТРОПО'ИД** *м.* — антропоид, кешесыман маймыл.

**АНТРОПО'ЛОГ** *м.* — антрополог, антропология белгече.

**АНТРОПОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — антропологик, антропология...-ы; *антропологический музей* — антропология музее.

**АНТРОПОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет —антропология (кешенең биологик табигатен һәр яктан өйрәнә торган фән).

**АНТРОПОМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет — антропометрия (антропологиянең кеше гәүдәсен һәм аның кисәкләрен үлчәү белән шөгыльләнә торган бүлеге).

**АНТРОПОМОРФИ'ЗМ** *м. мн.* нет — антропоморфизм (1. бик борынгы заманда — хайваннарның, үсемлекләрнең, табигать күренешләренең кешеләргә хас үзлекләре, ягъни фикерләре, тойгылары бар имеш дип ышану; 2. алла кеше сурәтендә була дип уйлау).

**АНТРОПОМОРФИ'ЧЕСКИЙ** — антропоморфик.

**АНТРОПОМО'РФНЫЙ** — кешесыман; *антропоморфные обезьяны* — кешесыман маймыллар.

**АНТРОПОФО'БИЯ** *ж.*— антропофобия, кешедән курку (авыру).

**АНТРОПОЦЕНТРИ'ЗМ** *м. мн.* нет — антропоцентризм (кешене галәмнең үзәге һәм дөнья яралуның иң ахыргы максаты дип таный торган, идеализм һәм дин белән бәйләнгән, фәнни булмаган караш).

**АНТУРА'Ж** *м.*— чолганыш, әйләнә-тирәдәге обстановка.

**АНФА'С** *нареч.*— анфас (1. караучыга йөз белән; 2. йөзнең алгы яктан төшерелгән рәсеме).

**АНФИЛА'ДА** *ж.*— анфилада (1. бер-бер артлы тезелеп киткән һәм берсеннән икенчесенә керү өчен бер үк турыда ишекләре булган бүлмәләр; 2. дошман фронты яки ныгытмалары сызыгы буйлап ату).

**АНЧА'Р** *м.*— анчар (агулы агач).

**АНЧО'УС** *м.*— анчоус (вак балык төре).

**АНЧО'УСНЫЙ** — анчоус...-ы; *анчоусные консервы* — анчоус консервасы.

**АНШЛА'Г** *м.*— аншлаг (театр билетлары сатылып бету турында белдерү, игълан).

**АНЮ'ТИНЫ ГЛА'ЗКИ** *бот.*— ала миләүшә.

**АО'РИСТ** *м. лингв.*— аорист (үткән заман фигыль формаларының берсенең исеме, башлыча: прошедшее совершенное).

**АО'РТА** *ж. анат.*— аорта (йөрәкнең сул ягыннан башланып китә торган төп кан тамыры).

**АПАРТА'МЕ'НТ** *м.* — апартамент (зиннәтле зур бүлмә яки квартира).

**АПАТИ'ЧЕСКИЙ, АПАТИ'ЧНЫЙ** — дәртсез, рухсыз, сүлпән, төшенке.

**АПАТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет—дәртсезлек, рухсызлык, сүлпәнлек, күңел төшенкелеге.

**АПА'ТИЯ** *ж.* — апатия, дәртсезлек, рухсызлык, сүлпәнлек, күңел төшенкелеге.

**АПАТРИ'ДЫ** — апатридлар (туган иленнән мәхрүм ителгәннәр; бер дәүләттә гражданлык хокукын югалтып, аны икенче дәүләттә дә ала алмаган кешеләр).

**АПА'Ш** *м.*—апаш(1. Франциядә—хулиган, бандит; 2. ачык киң якалы күлмәк).

**АПЕЛЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. *юр.* апелляция бирү (суд карарыннан риза булмыйча югары суд органнарына жалоба бирү); 2. *перен.* зарлану, кемнең дә булса хәлиткеч фикерен эзләү.

**АПЕЛЛЯ'НТ** *м.* — апеллянт (апелляцион жалоба бирүче).

**АПЕЛЛЯЦИО'ННЫЙ** — апелляция...-ы; *апелляционный срок* — апелляция срогы.

**АПЕЛЛЯ'ЦИЯ** *ж. юр.* — апелляция (суд карарыннан риза булмыйча югары суд органына бирелә торган жалоба).

**АПЕЛЬСИ'Н** *м.*— әфлисун.

**АПЕЛЬСИ'ННЫЙ, АПЕЛЬСИ'НОВЫЙ** — әфлисун...-ы; *апельсинное (апельсиновое) варенье* — әфлисун вареньесы.

**АПЛОДИ'РОВАТЬ** *несов.*— кул чабу (алкышлап).

**АПЛОДИСМЕ'НТЫ** *мн.* — кул чабулар (алкышлап).

**АПЛО'МБ** *м. мн.* нет — апломб (кыланышта, сүздә һәм эштә кыюлык, үз-үзенә ышану).

**АПОГЕ'Й** *м. мн.* нет — 1. *астр.* апогей (ай орбитасының җирдән иң ерак торган ноктасы); 2. *перен.* иң югары дәрәҗә, иң югары нокта; *его талант достиг своего апогея* — аның таланты үзенең иң югары ноктасына җитте.

**АПО'КОПА** *ж. лингв.*— апокопа (сүзнең ахырында бер яки берничә авазның төшүе, мәсәлән, бара алмады урынына баралмады).

**АПО'КРИФ** *м.* — апокриф (1. диннең рәсми өйрәтүләреннән беркадәр читкә тайпылган дини китаплар; 2. чын дип йөртелә торган ялган әсәр).

**АПОКРИФИ'ЧЕСКИЙ, АПОКРИФИ'ЧНЫЙ** — ялган, ышанычсыз, уйдырма.

**АПОЛИТИ'ЗМ, АПОЛИТИЦИ'ЗМ** *м.*— аполитизм (хезмәт ияләренә чит булган идеологияне яшерү өчен политика мәсьәләләренә кул селтәгән булып кылану; политик тормышка катнашудан баш тарту).

**АПОЛИТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет— политикадан читтәлек, политикадан читтә тору.

**АПОЛИТИ'ЧНЫЙ** — политикадан чит, политикадан читтә тора торган.

**АПОЛЛО'Н** I *м.* — аполлон (1. борынгы грек мифологиясендә кояш алласы, сәнгатьләрне яклаучы алла; 2. *перен.* матур ир кеше).

**АПОЛЛО'Н** II *м.*— *зоол.* аполлон (матур күбәләкләрнең бер төре).

**АПО'ЛОГ** *м.*— аполог, мәсәл.

**АПОЛОГЕ'Т** *м.* — апологет (нинди дә булса бер идеяне, тәгълиматны яклаучы).

**АПОЛОГЕ'ТИКА** *ж.*— апологетика (1. берәр нәрсәне объектив рәвештә тикшерү урынына, якламас урында яклау, мактау; 2. дин өйрәтмәләренең динне яклауга багышланган бүлеге).

**АПОЛОГИ'СТ** *м.*— к. апологет.

**АПОЛО'ГИЯ** *ж.* — апология (берәр шәхесне, идеяне, тәгълиматны яклау, мактау).

**АПОПЛЕКСИ'ЧЕСКИЙ** — апоплексик; *апоплексический удар* — апоплексик удар (паралич сугу).

**АПОПЛЕ'КСИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— апоплексия (мигә кан йөгерү аркасында паралич сугу).

**АПОПЛЕКТИ'ЧЕСКИЙ** — к. апоплексический.

**АПО'РТ** I *м.*— апорт (алма төре).

**АПО'РТ** II *межд.* — китер! бир! (эткә эндәшеп әйтелә).

**АПОСТЕРИО'РИ** *нареч. филос.* — тәҗрибәдән чыгып, тәҗрибә нигезендә.

**АПОСТЕРИО'РНЫЙ** — апостериор, тәҗрибәгә нигезләнгән; *апостериорное суждение* — апостериор хөкем, тәҗрибәгә нигезләнгән хөкем.

**АПО'СТОЛ** *м. церк.* — апостол (1. евангелиедә — Гайса шәкертләренең берсе; 2. *перен.* үзен берәр идеяне таратуга багышлаган кеше; 3. дини китапларның берсенең исеме).

**АПО'СТРО'Ф** *м.* — апостроф (сузык аваз хәрефе төшкәнлекне белдерү өчен хәрефләр арасында куелган өтерсыман билге).

**АПОСТРО'ФА** *ж.* — апострофа (юк кешегә бар кеше дип, яки җансыз предметка җанлы предмет дип мөрәҗәгать итүдән гыйбарәт булган стилистик алым).

**АПОФЕО'З** *м.* — апофеоз (1. шәхесне яки вакыйганы олылау; 2. вакыйганы тантаналы рәвештә тәгәлләү; 3. кайбер спектакльләрдә соңгы тантаналы картина).

**АПОФТЕ'ГМА** *ж.* — апофтегма (үткен фикерле кыска гына мәкаль, афоризм).

**АППАРА'Т** *м.* — 1. *тех.* аппарат, прибор; 2. *анат.* органнар (мәс., ишетү органнары); 3. *адм.* аппарат (учреждение яки бер үк өлкәгә караган учреждениеләр; берәр учреждениенең штатындагы барлык работниклар). ◇ **Научный аппарат** — гыйльми хезмәтләрдә бирелгән искәрмәләр, комментарийлар, күрсәтмәләр.

**АППАРАТУ'РА** *ж. мн.* нет, *собир.* — аппаратура, аппаратлар.

**АППАРА'ТЧИК** *м.* — аппаратчы, аппаратчик (аппаратларда эшләүче эшче).

**АППЕ'НДИКС** *м.* — аппендикс (1. *анат.* сукыр эчәкнең үсентесе; 2. *тех.* һава шары тышчасының түбәнге өлешендәге үсенте; ул һава шарына газ тутыру һәм артык газны чыгару өчен кулланыла).

**АППЕНДИЦИ'Т** *м. мед.* — аппендицит (сукыр эчәк үсентесенең ялкынсынуы, шешүе).

**АППЕРЦЕ'ПЦИЯ** *ж. псих.* — апперцепция (үзләштерүнең элек алынган белемнәргә, тәҗрибәләргә, күзаллауларга бәйле булуы).

**АППЕРЦЕПИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — апперцепцияләү (булган тәҗрибә нигезендә үзләштерү).

**АППЕРЦЕПИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — апперцепцияләнү (булган тәҗрибә нигезендә үзләштерелү).

**АППЕТИ'Т** *м.* — аппетит (1. *только ед.* ашыйсы килү; 2. теләк, омтылыш, комсызлык). ◇ **Приятного аппетита** — ашыгыз тәмле булсын.

**АППЕТИ'ТНЫЙ** — 1. аппетитлы, сокландыргыч; 2. аппетитны ача торган; *аппетитные капли* — аппетит ача торган тамчылар (дару).

**АППЛИКАЦИО'ННЫЙ** — аппликация...-ы; *аппликационная работа* — аппликация эше.

**АППЛИКА'ЦИЯ** *ж.* — аппликация (1. кәгазьгә яки тукымага төрле төстәге кәгазь, күн яки материя кисәкләре ябыштыру яки тегеп кую юлы белән орнаментлар, художестволы сурәтләр ясау; 2. аппликация юлы белән ясалган сурәт, рәсем, орнамент).

**АППО'РТ** *межд.* — к. апорт II.

**АППРЕТИ'РОВАТЬ** *сов.* — тәмам эшкәртеп бетерү (тукыманы, мехны һ. б.).

**АППРЕТУ'РА** *ж. хим.* — аппретура (1. тукыманы, эрләнгән җепне, күнне, мехны махсус матдәләр белән тәгәл эшкәртү; 2. күн өчен лак).

**АППРЕТУ'РНЫЙ** — аппретура...-ы; *аппретурный цех* — аппретура цехы.

**АПРЕ'ЛЬ** *м.* — апрель.

**АПРЕ'ЛЬСКИЙ** — апрель...-ы; *апрельские дни* — апрель көннәре.

**АПРИО'РИ** *нареч.* — 1. *филос.* (*независимо от опыта*) тәҗрибәгә нигезләмичә; 2. (*заранее, наперёд*) алдан.

**АПРИО'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *филос.* — априорлык, тәҗрибәгә нигезләнмәгәнлек.

**АПРИО'РНЫЙ** — априор, тәҗрибәгә нигезләнмәгән; *априорное утверждение* — тәҗрибәгә нигезләнмәгән раслау.

**АПРОБА'ЦИЯ** *ж.* — 1. апробация, раслау (рәсми рәвештә); 2. *агр.* проба алу (ашлыкның чисталыгын, сортын һ. б. тикшерү өчен).

**АПРОБИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — апробацияләү, апробация бирү, раслау.

**АПРОБИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — апробацияләнү, апробация бирелү, раслану.

**АПТЕ'КА** *ж.* — аптека. ◇ **Как в аптеке** — төп-төгәл, аптекада үлчәнгән кебек.

**АПТЕ'КАРСКИЙ** — аптека...-ы; *аптекарские товары* — аптека товарлары.

**АПТЕ'КАРША** *ж.* — 1. аптекарь хатыны; 2. аптекада эшләүче (хатын-кыз).

**АПТЕ'КАРЬ** *м.* — аптекарь, аптекада эшләүче.

**АПТЕ'ЧКА** *ж.* — аптечка (беренче ярдәм күрсәтү өчен кирәкле дарулар; шул дарулар саклана торган тартма).

**АПТЕ'ЧНЫЙ** — аптека...-ы; *аптечный склад* — аптека склады.

**АР** *м.* — ар (100 *кв.* метрга тигез җир үлчәве берәмлеге).

**АРА'Б** *м.* — гарәп.

**АРАБЕ'СК** *м.*, **АРАБЕ'СКА** *ж.* — 1. *архит.* арабеск (яфрак, чәчәк, геометрик фигуралар рәсемнәреннән төзелгән бизәкле орнамент); 2. *только мн.* вак әдәби (музыкаль) әсәрләр җыентыгы.

**АРАБИ'ЗМ** *м. лингв.* — 1. гарәпчелек (нинди дә булса бер телдә гарәп теле үрнәгендә төзелгән әйләнмә); 2. гарәп теленнән алынган сүз.

**АРАБИ'Н** *м.* — арабин (үсемлектән алына торган җилемнең бер төре).

**АРАБИ'СТ** *м.* — гарәп теле һәм әдәбияты белгече.

**АРАБИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — арабистика (гарәп телен, әдәбиятын, культурасын һәм тарихын өйрәнә торган фәннәр).

**АРА'БКА** *ж.* — гарәп хатын-кызы.

**АРА'БСКИЙ** — гарәп...-ы; *арабский язык* — гарәп теле.

**АРА'БЫ** *мн.* — гарәп халкы, гарәпләр.

**АРАВИ'ЙСКИЙ** — Гарәбстан...-ы; *аравийские пустыни* — Гарәбстан чүлләре.

**АРАВИТЯ'НИН** (*мн.* аравитяне) *м.*— Гарәбстанда яшәүче.

**АРА'ВИЯ** *ж.*— Гарәбстан.

**АРАКЧЕ'ЕВЩИНА** *ж. мн.* нет — аракчеевчылык (1. *ист.* идарәдә каты хәрби система; 2. *перен.* иҗтимагый тормышның берәр өлкәсендә башбаштаклык, критикага юл куймау режимы).

**АРА'П** I *м. простореч. устар.* — негр, кара тәнле кеше.

**АРАП** II *м. простореч., неодобр.* — алдакчы. ◇ **Заправлять арапа** *простореч.* — алдау. **Играть на арапа** *простореч.*— алдашып уйнау, хәрәмләшеп уйнау, акча салмыйча уйнау (оттырса түләмәс өчен).

**АРА'ПНИК** *м.* — эт чыбыркысы (аучыларда).

**АРА'Т** *м.*—арат (Монголиядә көтүче, терлек асраучылык белән көн күрүче хезмәт иясе).

**АРА'ТСТВО** *ср. мн.* нет — аратлар; *монгольское аратство объединяется в кооперативы* — Монголия аратлары кооперативларга берләшәләр.

**АРА'ХИС** (земляной орех) *м. бот.*— арахис, җир чикләвеге, Кытай чикләвеге.

**АРБИ'ТР** *м.*— арбитр (1. *юр.* третейский суд члены; 2. *спорт.* ярышлы уеннарда ике якның ризалыгы белән сайланып куелган судья; 3. Советлар Союзында — учреждениеләр, предприятиеләр арасындагы бәхәсле мәсьәләләрне тикшереп хәл кылучы хезмәткәр).

**АРБИТРА'Ж** *м.* — арбитраж (1. чит илләрдә — ике якның бәхәсен тикшереп хәл итә торган третейский суд; СССРда — дәүләт предприятиеләре һәм учреждениеләре арасында мөлкәт турында килеп чыккан бәхәсле мәсьәләләрне тикшереп хәл итүче орган; 2. капиталистик илләрдә биржада йөри торган бердәй вексельләр, кыйммәтле кәгазьләр, товарлар бәясе арасындагы аерманы файдаланудан гыйбарәт булган спекулятив эшчәнлек; 3. халыкара арбитраж— дәүләтләр арасындагы бәхәсне тыныч юл белән хәл итүнең бер ысулы).

**АРБИТРА'ЖНЫЙ** — арбитраж...-ы; *арбитражная комиссия* — арбитраж комиссиясе.

**АРБУ'З** *м.*— карбыз.

**АРБУ'ЗНЫЙ** — карбыз...-ы; *арбузная корка* — карбыз кабыгы.

**АРГА'Л** *м.* — кипкән тизәк (ягу өчен кулланыла).

**АРГЕНТИ'НЕЦ** *м.*— аргентиналы.

**АРГЕНТИ'НКА** *ж.*— аргентиналы хатынкыз.

**АРГЕНТИ'НСКИЙ** — Аргентина...-ы; *аргентинский пароход* — Аргентина пароходы.

**АРГЕНТИ'НЦЫ** — аргентиналылар, Аргентина халкы.

**АРГО'** *ср. нескл. лингв.* — арго (аерым бер социаль группа кешеләре арасында гына кулланыла торган сүзләр һәм шундый сүзләр белән тулган бер жаргон.)

**АРГОТИ'ЗМ** *м. лингв.* — арготизм, арголык (стилистик алым буларак телгә арго сүзләрен кертү).

**АРГОТИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.*— аргоча...; арго сүзләре белән...; *арготическое выражение*— аргоча әйтү; арго сүзләре белән әйтү.

**АРГОТИ'ЧНЫЙ** — к. арготический.

**АРГУМЕ'НТ** *м.*— 1. аргумент, дәлил, нигез; 2. *мат.* бәйсез үзгәрешле зурлык.

**АРГУМЕНТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет— 1. *(действие)* нигезләү, дәлилләр китерү, аргументлау; 2. *(совокупность аргументов)* дәлилләр, нигезләр, аргументлар.

**АРГУМЕНТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— дәлилләр китерү, исбат итү, нигезләү, аргументлау.

**АРГУМЕНТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— исбат ителү, нигезләнү, дәлилләр китерелү, аргументлану.

**А'РГУС** *м.* — аргус (1. борынгы грек мифологиясендә — күп күзле, гаять зур гәүдәле сакчы; 2. *перен.* сизгер сакчы; 3. *зоол.* фазаннар семьялыгыннан кош).

**АРЕ'Д** *м. простореч.*— карун, саран, явыз карт.

**АРЕ'ДОВ: аредовы веки жить** *простореч.*— күп яшәү, озын гомерле булу.

**АРЕ'НА** *ж.*— 1. арена (а. борынгы Рим амфитеатрында гладиаторлар көрәшә торган урын; б. циркта артистлар уйный торган түгәрәк мәйдан); 2. *перен.* мәйдан, арена; *арена политической борьбы* — политик көрәш мәйданы (аренасы).

**АРЕ'НДА** *ж.*— 1. *(наём)* аренда (күчми торган милекне вакытлыча файдалану өчен хак түләп алу яки хак алып файдалануга бирү); 2. *(плата)* аренда хакы, аренда түләве; *платить аренду* — аренда хакын түләү.

**АРЕНДА'ТОР** *м.* — арендатор, арендага алучы.

**АРЕНДА'ТОРСКИЙ** — арендатор...-ы, арендаторлык...-ы; *арендаторское право*— арендатор (арендаторлык) хокукы.

**АРЕ'НДНЫЙ** — аренда...-ы; *арендная плата* — аренда хакы.

**АРЕНДОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — арендага алу, арендовать итү, арендалау.

**АРЕНДОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— арендага алыну, арендовать ителү, арендалану.

**АРЕОПА'Г** *м. устар.*—1. *истор.* ареопаг (борынгы Афинада югары суд трибуналы); 2. *ирон.* тәнкыйтьчеләр; *литературный ареопаг* — әдәби тәнкыйтьчеләр.

**АРЕ'СТ** *м.*— 1. арест, кулга алу, сак астына кую; 2. *(запрещение)* арест (акчадан, яки мөлкәттән файдаланудан тыю); *наложить арест на имущество* — мөлкәткә арест салу.

**АРЕСТА'НТ** *м. устар.*— арестант (халык телендә „ристан"), тоткын, кулга алынган, төрмәгә ябылган кеше.

**АРЕСТА'НТКА** *ж.* — арестантка, тоткын хатын-кыз.

**АРЕСТА'НТСКИЙ** *устар.* — арестантлар...-ы; *арестантский халат* — арестантлар халаты.

**АРЕСТА'НТСКАЯ** *ж. сущ.*— арестантлар йорты.

**АРЕ'СТНЫЙ** — ябу...-ы; ябылу...-ы; *арестный дом* — ябу йорты.

**АРЕСТОВА'ТЬ** *сов.* — 1. кулга алу, арестовать иту; 2. *юр.* арест салу; *арестовать имущество* — милеккә арест салу.

**АРЕСТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — кулга алыну, арестовать ителү.

**АРЕСТО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. арестовать.

**АРЕСТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. арестоваться.

**АРИА'ДНИНА НИТЬ** — Ариадна җебе (*перен.* авыр хәлдән котылуга, берәр читен мәсьәләне чишүгә ярдәм итәрлек фикер).

**АРИЕРГА'РД** *м.* — к. арьергард.

**АРИ'ЙЦЫ** — ариецлар, арийлар (буржуаз фәндә һинд-европалыларның гомуми исеме).

**АРИСТОКРА'Т** *м.* — 1. аристократ, аксөяк (дворяннарның, буржуазиянең югары катлавы); 2. *ирон. перен.* аристократ (үзен башкалардан югары һәм аерым тотучы кеше).

**АРИСТОКРАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — аристократизм, аристократлык.

**АРИСТОКРАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. аристократик, аристократлар...-ы; *аристократическое общество* — аристократлар җәмгыяте, аристократик җәмгыять; 2. аристократларча; *аристократическая манера* — аристократларча кыланыш.

**АРИСТОКРАТИ'ЧНЫЙ** — к. аристократический 2.

**АРИСТОКРАТИ'Я** *ж. мн.* нет — 1. *собир.* аристократия, аксөякләр (эксплуатацияләүче сыйныфларның югары катлавы); 2. *истор.* аристократия (власть байлар һәм аристократлар кулында булган дәүләт төзелеше формасы); 3. *собир.* аристократлар (капиталистик илләрдә нинди дә булса бер сыйныфның яки иҗтимагый группаның өстен катлавы). ◇ **Аристократия ума, таланта** *книж.* — акыл ияләре, талантлы кешеләр.

**АРИСТОКРА'ТКА** *ж.* — аристократ хатын-кыз.

**АРИСТО'Н** *м. муз.* — аристон (механик рәвештә уйный торган ящиксыман музыка коралы).

**АРИТМИ'ЧЕСКИЙ** — к. аритмичный.

**АРИТМИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ритм юклык, ритмсызлык.

**АРИТМИ'ЧНЫЙ** — ритмсыз.

**АРИТМИ'Я** *ж. мн.* нет — 1. ритмсызлык, ритм юклык; 2. *мед.* йөрәкнең ритмы бозылуы, йөрәкнең дөрес типмәве.

**АРИФМЕ'ТИКА** *ж. мн.* нет — арифметика, хисап фәне (математиканың төп өлеше).

**АРИФМЕТИ'ЧЕСКИЙ** — арифметик, арифметика...-ы; *арифметические задачи* — арифметик мәсьәләләр; *арифметические термины* — арифметика терминнары.

**АРИФМО'ГРАФ** *м.* — арифмограф (автомат рәвештә язып бара торган хисап машинасы).

**АРИФМО'МЕТР** *м.* — арифмометр (арифметик гамәлләрне механик рәвештә исәпләп чыгару приборы).

**А'РИЯ** *ж. муз.* — ария (оркестрга кушылып бер генә кеше җырлый торган әсәр, гадәттә операның бер өлеше).

**А'РКА** *ж. архит.* — а́рка (1. стенадагы куышның көймәләп ясалган түбәсе (түшәме); ике багана арасында көймәләп ясалган түбә; 2. күперләрдә ике багана арасындагы торыклар). ◇ **Триумфальная а́рка** — триумф капкасы (берәр тантана уңае белән юл өстенә ясалган капка).

**АРКА'Д** *м. мн.* нет, *бот.* — аркад (тәмле хуш исле алма сорты).

**АРКА'ДА** *ж. архит.* — арка́да (а́ркалар тезмәсе).

**АРКА'ДИЯ** *ж. мн.* нет — 1. *истор.* Аркадия (борынгы Грециядә өлкә исеме); 2. *перен., поэт., ирон.* мәңге рәхәт яшәү иле, гамьсез тормыш иле, ваемсыз яшәү урыны.

**АРКА'ДСКИЙ** — Аркадия...-ы; *аркадский пастушок* — Аркадия көтүчесе (идиллик поэзиядә — гамьсез, рәхәт яшәүче кеше).

**АРКА'Н** *м.* — аркан, юан бау.

**АРКА'НИТЬ** *несов.* — аркан ыргытып тоту, аркан белән тоту (атны).

**АРКО'** *ср.* — арко, ялган алтын (бакыр белән цинк эретмәсе; төсе белән алтынга охшаган).

**А'РКТИКА** *ж. мн.* нет — Арктика (җир шарының төньяк поляр өлкәсе).

**АРКТИ'ЧЕСКИЙ** — Арктика...-ы; *арктическая комиссия* — Арктика комиссиясе; *арктические страны* — Арктика илләре.

**АРЛЕКИ'Н** *м.* — 1. *театр.* арлекин (Италиядә комик артист); 2. *перен.* шамакай, шут, сарай мәзәкчесе.

**АРЛЕКИНА'ДА** *ж.* — 1. *театр.* арлекинада (төп рольне арлекин уйный торган пьеса); 2. *перен.* шамакайлану.

**АРЛЕКИ'НСКИЙ** — арлекин...-ы; *арлекинский костюм* — арлекин костюмы.

**АРМА'ДА** *ж. истор.* — армада (зур хәрби флот); *воздушная армада* — зур һава флоты.

**АРМАТУ'РА** *ж. тех.* — арматура (1. электр уты үткәрү өчен кирәк булган әйберләр; 2. төзелеш эшләрендә металл чыбыклардан ясалып, соңыннан бетон тутырыла торган корылма — каркас; 3. нинди дә булса оборудованиедә вак приборлар һәм җайланмалар; 4. *архит.* стеналарны корал сурәтләре белән бизәү).

**АРМАТУ'РНЫЙ** — арматур ...-ы, арматура ...-ы; *арматурный список* — арматур исемлек (хәрби хезмәткәргә бирелгән киемнәр һәм әйберләр исемлеге); *арматурные материалы* — арматура материаллары.

**АРМАТУ'РЩИК** *м.* — арматурщик, арматурчы, арматура хәзерләүче (эшче).

**АРМЕ'ЕЦ** *м.* — армеец, армиядә хезмәт итүче, гаскәри.

**АРМЕ'ЙСКИЙ** — армия...-ы; *армейский тыл* — армия тылы.

**А'РМИЯ** *ж.* — 1. армия, гаскәр; *Советская Армия* — Совет Армиясе; *Первая Конная армия* — Беренче Атлы армия; 2. *перен.* армия (күп халык, зур халык төркеме); *армия безработных* — эшсезләр армиясе. ◇ **Действующая армия** — хәрәкәттәге армия (сугыштагы барлык гаскәрләр). **Всемирная армия труда** — бөтендөнья про-

летариаты. **Свинцовая армия** *устар.* — типография работниклары.

**АРМЯ'ЖНЫЙ** — к. армячный.

**АРМЯ'К** *м.* — чикмән.

**АРМЯ'НЕ** *мн.* — әрмәннәр, әрмән халкы.

**АРМЯНИ'Н** *м.* — әрмән.

**АРМЯ'НКА** *ж.* — әрмән хатын-кызы.

**АРМЯ'НСКИЙ** — әрмән...-ы, әрмәннәр...-ы; *армянский язык* — әрмән теле; *армянское блюдо* — әрмәннәр ашамлыгы.

**АРМЯ'ЧИНА** *ж. мн.* нет — чикмәнлек (дөя йонынан сугылган тула).

**АРМЯ'ЧНЫЙ** — 1. чикмәнлек...; *армячный материал* — чикмәнлек материал; 2. чикмән...-ы; *армячный рукав* — чикмән жиңе.

**АРНАУ'ТКА** *ж. мн.* нет, *бот.*, *с.-х.* — арнаутка (каты бодай сорты).

**АРНИ'КА** *ж. мн.* нет — 1. *бот.* үгез күзе; 2. *(лекарство)* арника (шул үсемлекнең чәчәкләреннән хәзерләнгән дару).

**АРО'ЙНИК** *м. бот.* — аройник, елан ястыгы.

**АРОМА'Т** *м.* — 1. аромат, хуш ис; 2. *только мн.* хуш исле (тәмле исле) матдәләр. ◇ **От этой книги веет ароматом высокой образованности** — бу китаптан зур белемлелек аңкып тора.

**АРОМАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. хуш исле; *ароматическая вода* — хуш исле (тәмле исле) су; 2. хуш исле матдәләрдән (ароматтан) хәзерләнгән.

**АРОМАТИ'ЧНЫЙ** — к. ароматный, ароматический.

**АРОМА'ТНЫЙ** — хуш исле, тәмле исле, ароматлы; *ароматный чай* — хуш исле чәй.

**А'РОЧНЫЙ** — арка...-ы; аркалы; *арочные столбы* — арка баганалары; *арочное сооружение* — аркалы корылма.

**АРСЕНА'Л** *м.* — 1. арсенал (а. *воен.* сугыш кораллары һәм хәрби әйберләр склады; б. сугыш кораллары хәзерләүче учреждение; в. *устар.* төрле дәвернең сугыш кораллары музее); 2. *перен.* күп нәрсә, хисапсыз күп запас; *в его распоряжении целый арсенал пособий* — аның карамагында ярдәмлекләр хисапсыз күп.

**АРТА'ЧИТЬСЯ** *несов.* *разг.* — карышу, киреләнү, тискәреләнү, кәҗәләнү; *(о лошади)* чыгымлау, чыгымчылау.

**АРТДИВИЗИО'Н** *м.* (артиллерийский дивизион) *воен.* — артдивизион (артиллерия дивизионы).

**АРТЕЗИА'НСКИЙ КОЛО'ДЕЦ** *м.* — артезиан коесы (суы җир астыннан үз басымы белән труба буйлап күтәрелә торган кое).

**АРТЕ'ЛЬ** *ж.* — 1. артель (берничә яки күп кешеләрнең бергә эшләү өчен берләшүләре); *сельхозартель* — авыл хуҗалыгы артеле; *артель инвалидов* — инвалидлар артеле; 2. *перен. разг.* артель, бер төркем кеше; *ходить целой артелью* — артель белән йөрү.

**АРТЕ'ЛЬНЫЙ** — 1. артель...-ы; *артельное хозяйство* — артель хуҗалыгы; 2. гомуми, уртак; *артельный хлеб* — гомуми (уртак) икмәк, артель икмәге; 3. *просторечн.* *(общительный)* аралашучан, кешегә катнашучан, тиз дусланучан.

**АРТЕ'ЛЬЩИК** *м. устар.* — артельщик, артель члены.

**АРТЕРИОСКЛЕРО'З** *м. мед.* — артериосклероз (артерияләнең калынаюы һәм катылануы).

**АРТЕ'РИЯ** *ж. мед.* — 1. артерия (йөрәктән чыккан канны тәннең бөтен органнарына тарата торган тамыр); 2. *перен.* артерия, төп юл (ил өчен әһәмияте зур булган бәйләныш юлы); *Волга — одна из главных артерий нашей страны* — Волга — безнең илебезнең төп артерияләренең берсе.

**АРТИ'КЛЬ** *м. грам.* — артикль (кайбер телләрдә билгелелекне яки билгесезлекне белдерү өчен исемнәргә өстәлә торган кисәкчә; мәсәлән, немец телендә: der, die, das, ein, eine).

**АРТИ'КУЛ** I *м. устар.* — артикул (законда, договорда статья, отдел, параграф). ◇ **Воинские артикулы** *истор.* — Пётр I нең хәрби законнары.

**АРТИ'КУЛ** II *м.* — артикул (товарның тибы).

**АРТИКУ'Л** *м. воен.*, *истор.* — артикул (корал тоту ысуллары). ◇ **Выкидывать артикулы** — уен чыгару, мәзәк ясау.

**АРТИКУЛИ'РОВАТЬ** *несов. лингв.* — артикуляция ясау, артикуляцияләү (сөйләү органнарын хәрәкәткә китереп авазлар ясау).

**АРТИКУЛЯЦИО'ННЫЙ** *лингв.* — артикуляцион, артикуляция...-ы; *артикуляционная база* — артикуляцион база.

**АРТИКУЛЯ'ЦИЯ** *ж.* — артикуляция (1. *анат.* буын; 2. *лингв.* билгеле бер авазны әйткәндә сөйләү органнарының хәрәкәте).

**АРТИЛЛЕРИ'ЙСКИЙ** — артиллерия...-ы; *артиллерийский снаряд* — артиллерия снаряды. ◇ **Артиллерийский обстрел** — тупка тоту.

**АРТИЛЛЕРИ'СТ** *м.* — артиллерист.

**АРТИЛЛЕ'РИЯ** *ж.* — артиллерия (1. еракка ата торган зур сугыш коралларының гомуми исеме; 2. артиллерия кораллары белән эш итүче гаскәр; 3. утлы ату коралларының төзелеше һәм алардан ату турындагы фән). ◇ **Тяжёлая артиллерия** *перен.* — акрын кыймылдаучан кеше, мыштым кеше.

**АРТИ'СТ** *м.* — артист (1. сәнгать әсәрләрен халык алдында башкаручы; 2. *перен.* нинди дә булса берәр эшне оста башкаручы).

**АРТИСТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — артистизм, артистлык (артистлык эшенә сәләтлелек һәм шуңа бирелүчәнлек).

**АРТИСТИ'ЧЕСКАЯ** *сущ.* — артистлар бүлмәсе.

**АРТИСТИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — артистларча, оста итеп, бик оста.

**АРТИСТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. артистлык...-ы; артистларча...; *артистические манеры* — артистларча кыланыш; 2. оста эшләнгән; *эта работа — прямо артистическая* — бу эш бик оста эшләнгән.

**АРТИСТИ'ЧНОСТЬ** *м. мн.* нет — артистларча эшләнгәнлек, башкарылганлык, үтә осталык.

**АРТИСТИ'ЧНЫЙ** — артистка охшаган, артист кебек (артистлык сыйфатлары белән аерылып торган).

**АРТИ'СТКА** *ж.*— артистка.

**АРТНАЛЁТ'** (артиллерийский налёт) *м. воен.* — артиллерия налёты, артиллериядән ату.

**АРТНАСТУПЛЕ'НИЕ** (артиллерийское наступление) *ср.*— артиллерия һөҗүме.

**АРТПО'ЛК** (артиллерийский полк) *м. воен.*— артполк, артиллерия полкы.

**АРТСНАРЯ'Д** (артиллерийский снаряд) *м. воен.* — артснаряд, артиллерия снаряды.

**А'РФА** *ж.*— арфа (1. *муз.* өчпочмаксыман рамага кыллар тезеп ясалган музыка коралы; 2. *с.-х.* ашлык чистарту, сортлау машинасының бер төре).

**АРФИ'СТ** *м. муз.* — арфист, арфада уйнаучы.

**АРФИ'СТКА** *ж.* — арфистка, арфада уйнаучы хатын-кыз.

**АРХАИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — архаизация (сәнгатьнең борынгы формаларына иярү).

**АРХАИ'ЗМ** *м.* — 1. *лингв.* архаизм, борынгылык, искелек (кулланудан чыккан иске сүзләр яки әйтемнәр); 2. *книж.* искелек калдыклары.

**АРХАИ'СТИКА** *ж.*— архаистика (сәнгатьтә борынгы формаларга, борынгы ысулларга иярү).

**АРХАИ'ЧЕСКИЙ, АРХАИ'ЧНЫЙ** — 1. архаик, борынгы; *архаический стиль*—архаик стиль; 2. искергән, кулланудан чыккан.

**АРХАИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — борынгылык, искергәнлек.

**АРХАИ'ЧНЫЙ** — к. архаический.

**АРХА'НГЕЛ** *м.* — 1. *миф.* җәбраил фәрештә; 2. *перен. доревол. ирон.* жандарм, полицейский.

**АРХА'РОВЕЦ** *м. устар., бран.*— хулиган, башкисәр (XVIII йөздә Москва губернаторы Архаров исеменнән алынган).

**АРХЕ'ЙСКАЯ Э'РА** *геол.* — архей эрасы (җир тарихының иң борынгы эрасы).

**АРХЕО'ГРАФ** *м. филол.* — археограф (археография белгече).

**АРХЕОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *филол.*— археография...-ы; археографик; *археографическая комиссия* — археография комиссиясе.

**АРХЕОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *филол.* — археография (тарихның язма памятникларны җыя, өйрәнә һәм бастырып чыгара торган бүлеге).

**АРХЕО'ЛОГ** *м.* — археолог, археология белгече.

**АРХЕОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — археологик; археология...-ы; *археологические находки* — археологик табылдыклар; *археологическое отделение* — археология бүлеге.

**АРХЕОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — археология (табылган әйберләргә карап борынгы халыкларның тормышын, культурасын тикшерә торган фән).

**АРХИ'В** *м.* — архив (1. иске документлар саклана торган учреждение; 2. учреждениедә архив саклана торган бүлек яки бүлмә; 3. иске документлар, китаплар, газета-журналлар). ◇ **Сдать в архив** *перен.* 1. яраксызга чыгару; 2. искергән дип табу.

**АРХИВА'РИУС** *м.* — архивариус, архив мөдире.

**АРХИВИ'СТ** *м.* — архивист, архивчы, архив эшләре белгече.

**АРХИ'ВНЫЙ** — архив...-ы; *архивные дела* — архив эшләре.

**АРХИЕПИ'СКОП** *м. церк.* — архиепископ (христиан динендә рухани).

**АРХИЕРЕ'Й** *м. церк.* — архиерей (христиан динендә югары чиндагы руханиларның гомуми исеме).

**АРХИМАНДРИ'Т** *м. церк.* — архимандрит (монастырь башлыгы).

**АРХИПА'СТЫРЬ** *м. церк.* — архипастырь (христиан динендә югары дәрәҗәле руханиларның, патриархларның, митрополитларның, епископларның почётлы исеме).

**АРХИПЕЛА'Г** *м. геогр.* — архипелаг (берберләренә якын тора торган утраулар төркеме).

**АРХИПЛУ'Т** *м.* — үтә алдакчы, үтә хәйләкәр.

**АРХИТЕКТО'НИКА** *ж. мн.* нет — архитектоника (1. *геол.* геологиядә җир кабыгының төзелешен өйрәнә торган бүлек; 2. *архит.* аерым өлешләрнең үзара органик рәвештә ярашулары, матур, төзек булулары; 3. *искус.* сәнгать әсәренең төзелеше).

**АРХИТЕКТОНИ'ЧЕСКИЙ** — архитектоник; *архитектоническое исследование* — архитектоник тикшеренү.

**АРХИТЕ'КТОР** *м.* — архитектор, архитектура белгече.

**АРХИТЕ'КТОРСКИЙ** — архитектор... -ы, архитекторлык... -ы; *архитекторский проект* — архитектор проекты.

**АРХИТЕКТУ'РА** *ж. мн.* нет — архитектура (1. биналар салу сәнгате; 2. бинаның стиле).

**АРХИТЕКТУ'РНЫЙ** — архитектура... -ы; *архитектурные украшения* — архитектура бизәкләре.

**АРХО'НТЫ** *истор.* — архонтлар (борынгы Грециядә хөкүмәтнең иң югары кешеләре).

**АРШИ'Н** *м. устар.* — аршын (1. элекке озынлык үлчәве = 0,711 метр; 2. бер аршын озынлыктагы линейка). ◇ **Мерить на свой аршин** — үз аршынына үлчәү (мәсьәләгә берьяклы карау). **Как-будто аршин проглатил** — әйтерсең уклау йоткан (муеның бөкми торган, үрә каткан кешегә әйтелә).

**АРШИ'ННИК** *м. устар. разг.* — асламчы, вак сәүдәгәр (аршынлап кызыл мал сатып йөрүче).

**АРШИ'ННЫЙ** *устар.* — аршынлы; *пятиаршинный* — биш аршынлы.

**АРЬЕРГА'РД, АРИЕРГА'РД** *м. воен.* — арьергард (гаскәрнең төп көчләрдән артта бара торган частьлары).

**АРЬЕРГА'РДНЫЙ** *воен.* — арьергард...; *арьергардный отряд* — арьергард отряд.

**АС I** *м.* — ас (һава сугышларында үзенең осталыгын күрсәткән, билгеле санда дошман самолётларын бәреп төшергән очучы).

**АС II** *м.* — ас (борынгы Римда вак акча һәм үлчәү берәмлеге).

**АСБЕ'СТ** *м.* — к. азбест.

**АСЕЙСМИ'ЧЕСКАЯ О'БЛАСТЬ** *ж.* — асейсмик өлкә (җир тетрәү, селкенү булмый торган өлкә).

**АСЕКСУА'ЛЬНОСТЬ** *ж. биол. мед.* — 1. сексуальсезлек, җенес билгеләренең булмавы; 2. җенси дәрт белән мавыгуның булмавы.

**АСЕ'ПТИКА** *ж. мн.* нет, *мед.* — асептика (яраны микроблардан саклау чаралары).

**АСЕПТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — асептик, асептика... -ы; *асептические мероприятия* — асептика чаралары.

**АСЕ'ССОР** *м. истор.*: **коллежский асессор** — коллежский асессор (революциягә кадәр Россиядә казна палатасында утырышчы, член).

**АСИММЕТРИ'ЧЕСКИЙ, АСИМЕТРИ'ЧНЫЙ** — асимметрик, асимметрияле; симметриясез; *асимметрическое устройство* — асимметрик корылыш.

**АСИММЕ'ТРИ'Я** *ж. мн.* нет — асимметрия, симметриясезлек (форманың төзек булмавы).

**АСИНХРО'ННЫЙ** — асинхронлы (бер үк вакытта булмый торган).

**АСКЕ'Т** *м.* — 1. *истор. рел.* аскет (борынгы заманда христиан динендә монах); 2. *перен.* дәрвиш, суфый, тәкъва (дөнья рәхәтеннән ваз кичкән, баш тарткан кеше).

**АСКЕТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — 1. аскетизм, суфыйлык; 2. *перен.* дөнья рәхәтеннән баш тарту.

**АСКЕТИ'ЧЕСКИЙ** — аскетлар... -ы; аскетларча...; *аскетическая жизнь* — аскетлар тормышы, аскетларча яшәү.

**АСОЦИА'ЛЬНЫЙ** — асоциаль, җәмгыятькә каршы (җәмгыятьнең хокукларын һәм бурычларын боза торган).

**АСПЕ'КТ** *м.* — аспект, караш; *он изложил вопрос в следующем аспекте* — ул мәсьәләне түбәндәге караштан чыгып сөйләп бирде.

**А'СПИД** I *м.* — 1. *зоол.* аспид (кара еланның бер төре); 2. *перен. бран.* явыз, кара эчле, зәһәр (кеше).

**А'СПИД** II *м. мн.* нет, *мин.* — аспид, кара таш, кара сланец (грифель тактасы әзерләүгә китә торган катлы-катлы минерал).

**А'СПИДНЫЙ** — аспид... -ы; кара таштан ясалган, грифель... -ы; *аспидная доска* — грифель тактасы.

**АСПИРА'НТ** *м.* — аспирант (югары уку йортларында, гыйльми-тикшеренү институтларында укып гыйльми эшче булырга хәзерләнүче югары белемле кеше).

**АСПИРА'НТСКИЙ** — аспирант... -ы; аспирантлар... -ы; *аспирантская работа* — аспирант эше.

**АСПИРАНТУ'РА** *ж.* — 1. аспирантура (гыйльми эшчеләр хәзерләү системасы); 2. *собир.* аспирантлар.

**АСПИРИ'Н** *м. мн.* нет — аспирин (тәннең эсселеген киметә һәм авыртуны баса торган дару).

**АССАМБЛЕ'Я** *ж.* — ассамблея (1. төрле дәүләт вәкилләренең гомуми җыелышы; *Генеральная Ассамблея Организации Объединенных Наций* — Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генеральный Ассамблеясы; 2. *истор.* Пётр I заманында танец кичәләре).

**АССЕНИЗА'ТОР** *м.* — ассенизатор, бәдрәф чистартучы.

**АССЕНИЗАЦИО'ННЫЙ** — ассенизацион; ассенизация... -ы; *ассенизационный обоз* — ассенизацион обоз; *ассенизационная контора* — ассенизация конторасы.

**АССЕНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — ассенизация (пычракларны тазарту, түгү; санитария шартларын яхшырту).

**АССИГНА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *истор.* — ассигнация (Россиядә 1769 елда гамәлгә кертелгән кәгазь акча; ассигнация 1843 елда дәүләт кредит билетлары белән алыштырылган).

**АССИГНОВА'НИЕ** *ср.* — 1. к. ассигновать; 2. ассигновать ителгән акча, билгеләнгән акча.

**АССИГНОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — ассигновать итү, акча билгеләү, сметага кертү.

**АССИГНОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — билгеләнү, ассигновать ителү, сметага кертелү.

**АССИГНО'ВКА** *ж. фин.* — ассигновка (1. к. ассигнование; 2. билгеләнгән (ассигновать ителгән) акчаны ала торган документ).

**АССИГНО'ВЫВАТЬ** *несов. многокр.* — к. ассигновать.

**АССИГНО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. ассигноваться.

**АССИМИЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. ассимиляцияләү, сеңдерү, үзләштерү; 2. *лингв.* ассимиляцияләү (бер авазның икенче авазны үзенә охшатуы, яраштыруы).

**АССИМИЛИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — ассимиляцияләнү, үзләштерелү; охшашлану.

**АССИМИЛЯТИ'ВНЫЙ, АССИМИЛЯЦИО'ННЫЙ** — ассимилятив, ассимиляция... -ы; *ассимилятивный процесс* — ассимилятив процесс, ассимиляция процессы.

**АССИМИЛЯ'ЦИЯ** *ж.* — 1. *биол.* ассимиляция, сеңдерү, үзләштерү (тереклек иясе яки үсемлек организмының үзенә кергән матдәләрне эшкәртеп үзләштерүе); 2. *лингв.* ассимиляция, охшашлану (бер авазның икенче аваз белән охшашлануы, мәсәлән, урманлар-урманнар); 3. кушылу (бер халыкның телен, гореф-гадәтен, культурасын, динен үзләштерү нәтиҗәсендә икенче бер халыкның шул халык белән кушылуы).

**АССИРИ'ЙСКИЙ** — Ассирия...-ы; *ассирийская культура* — Ассирия культурасы.

**АССИРИ'ЙЦЫ** *мн.* (*ед.* ассириец) — ассириялеләр, Ассирия халкы.

**АССИРИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — ассириология (борынгы Ассириянең культурасын һәм чөйсыман язмаларын өйрәнә торган фән).

**АССИСТЕ'НТ** *м.* — ассистент (1. югары уку йортларында студентлар белән лаборатория эшләре һәм практик занятиеләр

алып баруда профессорның ярдәмчесе; операция ясаганда врачка ярдәм итүче; 2. экзамен вакытында экзаменаторның ярдәмчесе).

**АССИСТЕ'НТСКИЙ** — ассистентлар... -ы, ассистент... -ы, ассистентлык... -ы; *ассистентская комната* — ассистентлар бүлмәсе; *ассистентские обязанности* — ассистентлык бурычлары.

**АССИСТИ'РОВАТЬ** *несов.*—ассистентлык итү (мәсәлән, операция ясаганда врачка булышу, ярдәм итү).

**АССОНА'НС** *м.* — ассонанс (1. авазларның аһәңдәшлеге; 2. *поэт.* тулы булмаган рифма; шигырьдә сузыкларның гына рифмалашуы).

**АССОРТИМЕ'НТ** *м. торг.* — ассортимент (1. бер үк товарның төрле сорты; төрле товарлар; 2. бернәрсәгә караган төрле әйберләрнең тулы комплекты). ◇ **Принудительный ассортимент** — мәҗбүри ассортимент.

**АССОЦИАТИ'ВНЫЙ** — ассоциатив; *ассоциативная связь* — ассоциатив бәйләнеш.

**АССОЦИАЦИОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — ассоцианионизм (барлык катлаулы психик процессларны иң гади элементларның ассоциациясенә механик рәвештә кайтарып калдыра торган психологик теория).

**АССОЦИА'ЦИЯ** *ж.* — 1. (*объединение*) ассоциация, берләшмә; 2. ассоциация (а. *психол.* тиндәшлек, аерым төшенчәләр арасындагы бәйләнеш, бер төшенчәгә охшатып икенчесен искә төшерү; б. *хим.* молекулаларның ассоциацияләшүләре, берләшүләре; в. *бот.* үсемлекләрне классификацияләү берәмлеге).

**АССОЦИИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. псих.*— ассоциацияләү, ассоциация ясау.

**АССОЦИИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— ассоциацияләнү, ассоциация ясалу.

**АССР** (Автономная Советская Социалистическая Республика) — АССР (Автономияле Совет Социалистик Республикасы).

**АСТЕНИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — астеник; ябык, көчсез, зәгыйфь, хәлсез; *астенические явления* — астеник күренешләр; *астенический тип* — астеник тип (ябык, тар күкрәкле, озын гәүдәле кеше).

**АСТЕНИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — астения (көчсезлек, организмның көчсезлеге, организмның зәгыйфьлеге; психик көчсезлек).

**А'СТМА** *ж. мед.* — астма, буылу, тын бетү, күкрәк кысу (авыру).

**АСТМА'ТИК** *м. мед.* — астматик (күкрәк кысу белән авыручы кеше).

**АСТМАТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — бума ...-ы; астматик; *астматический приступ* — бума өянәге.

**А'СТРА** *ж. бот.* — кашкарый (бакча гөле).

**АСТРА'ЛЬНЫЙ** — йолдыз... -ы; *астральный свет* — йолдыз яктысы, йолдыз яктылыгы.

**АСТРАХА'НКА** *ж.*—1. (*сорт дыни*) Астрахань кавыны; 2. (*рыба*) Астрахань селёдкасы.

**АСТРО'ГРАФ** *м. астр.* — астрограф (күктәге йолдызларның рәсемен ала торган астрономик труба).

**АСТРО'ЛОГ** *м. устар.* — астролог, фалчы (астрология белән шөгыльләнүче).

**АСТРОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *устар.* — астрология (борынгы заманда, йолдызларның торышына карап кешенең язмышын алдан әйтеп була дип раслаган ялган караш).

**АСТРОНО'М** *м.* — астроном, астрономия галиме, астрономия белгече.

**АСТРОНОМИ'ЧЕСКИЙ** — 1. астрономик; *астрономические наблюдения* — астрономик күзәтүләр; 2. *перен.* бик зур, исәбенә чыкмаслык (саннар); *астрономические цифры* — астрономик саннар, исәбенә чыкмаслык саннар.

**АСТРОНО'МИЯ** *ж. мн.* нет — астрономия (йолдызларның һәм планеталарның төзелеше, табигате һәм хәрәкәт итүе законнарын өйрәнә торган фән).

**АСТРОСКО'П** *м.* — астроскоп (астрономик труба).

**АСТРОФИ'ЗИКА** *ж. мн.* нет — астрофизика (күк җисемнәренең составы һәм төзелеше, аларның физик һәм химик үзенчәлекләре турындагы фән).

**АСТРОФИ'ЧЕСКИЙ** — строфасыз, строфаларга бүленми торган; *астрофическое стихотворение* — строфасыз шигырь.

**АСФА'ЛЬТ** *м. мин.* — асфальт, тау сумаласы (урам һәм юлларга җәю өчен кулланыла).

**АСФАЛЬТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — асфальт җәю, асфальтлау.

**АСФАЛЬТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — асфальт җәелү, асфальтлану.

**АСФА'ЛЬТОВЫЙ** — асфальт..., асфальт җәелгән; *асфальтовая дорога* — асфальт юл, асфальт җәелгән юл.

**АСФАЛЬТОПОДО'БНЫЙ** — асфальтсыман.

**АСЬ** *межд.* — нәрсә? ни?

**АТАВИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *биол.* — атавизм (борынгы бабаларда булып та хәзер югалган билгеләрнең организмда яңадан килеп чыгуы).

**АТАВИ'ЧЕСКИЙ** *биол.* — атавизм... -ы; *атавический признак* — атавизм билгесе.

**АТА'ЙКА** *ж. зоол.* — атайка, кызыл үрдәк (төньяк диңгез кошы).

**АТА'КА** *ж.* — атака, омтылышлы һөҗүм.

**АТАКОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — атаковать итү, һөҗүм итү.

**АТАКОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — атакага эләгү, атаковать ителү.

**АТАМА'Н** *м.* — атаман (1. *истор.* казачи гаскәрләрдә һәм казачи округларда хәрби-административ начальник исеме; 2. *устар.* юлбасарлар башлыгы; 3. *перен. разг.* башлап йөрүче, берәр төркемнең башлыгы).

**АТАМА'НСКИЙ** — атаман... -ы, атаманлык... -ы; *атаманские замашки* — атаман (атаманлык) кыланышлары.

**АТАМА'НСТВО** *ср.* — атаманлык.

**АТАМА'НСТВОВАТЬ** *несов.* — 1. атаманлык итү, атаман булып тору; атаман булып йөрү; 2. *перен. разг.* башлык булып йөрү.
**АТА'РА** — к. отара.
**АТЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет — атеизм, динсезлек, алласызлык, дәһрилек.
**АТЕИ'СТ** *м.* — атеист, дингә (аллага) ышанмаучы, динсез, алласыз, дәһри.
**АТЕИСТИ'ЧЕСКИЙ** — атеистик, дингә каршы; *атеистическая пропаганда* — атеистик пропаганда, дингә каршы пропаганда.
**АТЕЛЬЕ'** *ср. нескл.* — ателье (1. сәнгать эшләре белән шөгыльләнүчеләр мастерское; 2. кием тегү мастерское).
**АТИПИ'ЧЕСКИЙ** — типик үзенчәлекләре булмаган, нормадан читкә чыккан.
**АТИ'ПИЯ** *ж.* — типик үзенчәлекләре булмау, нормадан читкә чыгу, тайпылу.
**АТЛА'НТ** I *м. мед.* — атлант, чалу сөяге (муенда беренче умыртка).
**АТЛА'НТ** II *м. архит.*—атлант (1. борынгы грек мифологиясендә баш һәм куллары белән күк гөмбәзен тотып торучы титан; 2. *архит.* түбәне, түшәмне күтәреп торгансыман итеп ясалган ир кеше сыны).
**А'ТЛАС** *м.* — атлас (1. тарихи, географик һ. б. карталар җыелмасы; 2. хайваннар, үсемлекләр рәсемнәренең җыелмасы).
**АТЛА'С** *м. текст.* — атлас (ефәк материя).
**АТЛА'СНЫЙ** — 1. атлас...; *атласное одеяло* — атлас юрган; 2. шома, ялтыравыклы.
**АТЛЕ'Т** *м.* — атлет (1. профессиональ көрәшче, атлетика белән шөгыльләнүче спортсмен; 2. *перен. разг.* физик яктан таза, көчле кеше).
**АТЛЕ'ТИКА** *ж. мн.* нет — атлетика (мускулларны ныгыту өчен булган физик күнегүләр); *лёгкая атлетика* — җиңел атлетика (йөгерү, сикерү һ. б.); *тяжёлая атлетика* — авыр атлетика (авырлык күтәрү, көрәшү, бокс).
**АТЛЕТИ'ЧЕСКИЙ** — атлетик; *атлетические упражнения* — атлетик күнегүләр.
**АТМОСФЕ'РА** *ж. мн.* нет — 1. атмосфера (җир шарын чолгап алган һава); 2. *физ.* атмосфера (газсыман әйберләрнең басымнарын үлчәү берәмлеге); 3. *разг.* (*воздух*) һава; *в комнате спёртая атмосфера* — бүлмәнең һавасы тынчу; 4. *перен.* әйләнә-тирә, тирә-юнь, чолганыш.
**АТМОСФЕРИ'ЧЕСКИЙ** — атмосфера...-ы; *атмосферические явления* — атмосфера күренешләре.
**АТМОСФЕ'РНЫЙ** — атмосфера... -ы; *атмосферное давление* — атмосфера басымы. ◇ **Атмосферные осадки** — явым-төшем (яңгыр, кар, кырау, чык һ. б.).
**А'ТОМ** *м.* — 1. *физ.* атом (химик элементның күзгә күренми торган бик кечкенә кисәкчәсе); 2. *перен.* зәррә (бик кечкенә нәрсә).
**А'ТОМНЫЙ** *хим.* — атом... -ы; *атомный вес* — атом авырлыгы; *атомная бомба* — атом бомбасы.
**А'ТОМЩИКИ** *мн.* (*ед.* атомщик) — атомчылар (тыныч халыкны күпләп кыру өчен атом бомбасын кулланырга омтылучы империалистлар).
**АТРАКЦИО'Н** *м. театр.* — к. аттракцион.
**АТРИБУ'Т** *м.* — 1. *филос.* атрибут (бер нәрсәнең төп билгесе); 2. *грам.* аергыч.
**АТРИБУТИ'ВНЫЙ** *лингв.* — атрибутив; *атрибутивная конструкция* — атрибутив конструкция.
**АТРИБУ'ЦИЯ** *ж.* — атрибуция (кем тарафыннан язылуы билгеле булмаган әсәрнең авторын һәм язылу дәверен белү).
**АТРОФИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — атрофияләнү.
**АТРОФИ'Я** *ж. мн.* нет, *книж.* — атрофия (1. *мед.* нинди дә булса бер органның туклану житешмәү сәбәпле кечерәюе һәм сәләтлелеген югалтуы; 2. *перен.* бетү, тупаслану (берәр тойгының).
**АТТАШЕ'** *м. нескл. дипл.* — атташе (посольствода махсус хезмәт йөкләтелгән сотрудник); *военный атташе* — хәрби атташе; *торговый атташе* — сәүдә атташесы.
**АТТЕСТА'Т** *м.* — аттестат (1. урта уку йортын тәмамлау турында рәсми документ; 2. *устар.* хезмәт иткән урыннан бирелә торган рекомендация; 3. *воен.* азыктөлек һәм акча белән тәэмин итү турында хәрби хезмәткәргә бирелә торган документ; 4. хәрби хезмәткәр семьясына, аның акчасын алырга хокук бирә торган документ; 5. нәселле терлекләргә бирелә торган документ). ◇ **Аттестат зрелости** — өлгергәнлек аттестаты (урта мәктәпне бетерү турында бирелгән язу).
**АТТЕСТАЦИО'ННЫЙ** — аттестация... -ы, аттестацион; *аттестационная комиссия* — аттестация комиссиясе; *аттестационное свидетельство* — аттестацион таныклык.
**АТТЕСТА'ЦИЯ** *ж.* — 1. (*действие*) аттестация, аттестацияләү, рекомендация бирү (житешле-житешсез якларны күрсәтү); 2. (*отзыв*) аттестация, аттестация язуы (кәгазе).
**АТТЕСТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. (*присвоить звание*) аттестовать итү, звание бирү; 2. (*дать отзыв*) отзыв бирү, (берәр кешенең теге яки бу якларын күрсәтеп) бәя бирү; 3. күрсәтү; *аттестовать себя* — үзен күрсәтү; *он аттестовал себя с плохой стороны* — ул үзен начар яктан күрсәтте.
**АТТЕСТОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. *страд.* аттестовать ителү, бәя бирелү; 2. үзен тәкъдим итү, тәкъдим итү; *он аттестовался мне родственником моего приятеля* — ул миңа үзен минем дустымның кардәше дип тәкъдим итте.
**АТТИ'ЧЕСКИЙ**: **аттическая соль** — оста рәвештә көлү, үткен сүзләр әйтеп көлү.
**АТ(Т)РАКЦИО'Н** *м. театр.* — аттракцион (цирк яки эстрада программасында тамашачыларның дикъкатен үзенә тарта торган иң эффектлы номер).
**АТТРИБУ'Т** *м.* — к. атрибут.
**АТТРИБУТИ'ВНЫЙ** — к. атрибутивный.
**АТУ'** *межд.* — „тот", „эләктер" мәгънәсендә ауда эт өстерү сүзе.

**АТУ'КАТЬ** *несов.* — „ату" дип кычкыру, өстерү.

**АУ'** *межд.* — һей!

**АУДИЕ'НЦИЯ** *ж.* — аудиенция, кабул итү (берәр югары дәрәҗәле кешенең рәсми рәвештә кабул итүе).

**АУДИ'ТОР** *м.* — аудитор (революциягә кадәр хәрби судларда прокурор хезмәтен үтәүче).

**АУДИТО'РИЯ** *ж.* — 1. (*помещение*) аудитория (югары уку йортларында лекция, доклад һ. б. укыла торган зал яки бүлмә); 2. *собир.* лекция (доклад) тыңлаучылар.

**АУДИТО'РНЫЙ** — аудиториядә үткәрелә торган; *аудиторные занятия* — аудиториядә үткәрелә торган занятиеләр.

**АУДИФО'Н** *м.* — аудифон (1. чукраклар өчен ишетүне көчәйтә торган аппарат; 2. *воен.* якынлашып килә торган дошман самолётының мотор тавышын тотып ала торган аппарат).

**АУ'КАТЬ** *сов.* и *несов.* — „һәй" дип кычкыру.

**АУ'КАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — „һәй" дип кычкырышу, эндәшешү (мәсәлән, урманда).

**АУ'КНУТЬ** *сов.* — „һәй" дип кычкырып кую.

**АУ'КНУТЬСЯ** *сов.* — 1. „һәй" дип җавап кайтару; 2. *разг.* кулдан ычкыну, югалу, эләкмәү; *я совсем было получил место, но в последнюю минуту оно мне аукнулось* — мин урынны алам дигәндә генә ул миңа эләкмәде.

**АУКЦИО'Н** *м.* — аукцион (берәр мөлкәтне яки товарны халык алдында артыграк бәя бирүчегә сату).

**АУКЦИОНИ'СТ** *м.* — аукционист, аукционда сатучы.

**АУКЦИО'ННЫЙ** — аукцион... -ы; *аукционная камера* — аукцион камерасы.

**АУТЕНТИ'ЧЕСКИЙ, АУТЕНТИ'ЧНЫЙ** — аутентик, чын, хакыйкый (төп нөсхәгә туры килә торган); *аутентичным считается текст закона, написанный на государственном языке* — дәүләт телендә язылган закон тексты аутентик булып санала.

**АУТОДАФЕ'** *ср. нескл. истор.* — к. автодафе.

**АФГА'НЕЦ** *м.* — афганлы.

**АФГА'НКА** *ж.* — афганлы хатын-кыз.

**АФГА'НСКИЙ** — афган... -ы, Афганстан... -ы; *афганская граница* — Афганстан чиге; *афганский язык* — афган теле.

**АФГА'НЦЫ** *мн.* — афганлылар, афган халкы.

**АФЕ'РА** *ж. разг.* — афера, алдау, хәйлә; хәйләле эш, хыянәтле эш, алдаулы эш.

**АФЕРИ'СТ** *м.* — аферист (афера белән шөгыльләнүче), жулик.

**АФИ'ША** *ж.* — афиша (театр, цирк һ. б. турында белдерү).

**АФИШИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — кешеләргә күрсәтү, кешеләрнең дикъкатен юнәлтү, кешеләр күрсен дип эшләү.

**АФИШИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кешеләргә күрсәтелү, күрсен дип эшләнү.

**АФИ'ШКА** *ж. разг.* — к. афиша.

**АФИ'ШНЫЙ** — афиша... -ы; *афишный шрифт* — афиша шрифты (афиша баса торган хәреф).

**АФОНИ'ЧЕСКИЙ** — тавышсыз, тавыш бетү... -ы, карлыгу... -ы; *афоническая болезнь* — тавыш бетү авыруы.

**АФОНИ'Я** *ж. мед.* — афония (тавыш бетү авыруы).

**АФОРИ'ЗМ** *м.* — афоризм, хикмәтле сүз (тирән мәгънәле кыска әйтем, мәсәлән, калган эшкә кар ява).

**АФОРИСТИ'ЧЕСКИЙ, АФОРИСТИ'ЧНЫЙ** — афоризм характерындагы, афористик; *афористическое выражение* — афористик әйтем, афоризм характерындагы әйтем.

**АФРИКА'НЕЦ** *м.* — африкалы, Африка кешесе.

**АФРИКА'НКА** *ж.* — африкалы хатын-кыз.

**АФРИКА'НСКИЙ** — Африка... -ы; *африканские народы* — Африка халыклары.

**АФРИКА'НЦЫ** *мн.* — африкалылар, Африка халыклары.

**АФРО'НТ** *м. устар.* — афронт, хурлык; *потерпеть афронт* — хурлыкка очрау, уңышсызлыкка очрау.

**АФФЕ'КТ** *м.* — 1. кызып китү, ярсу; 2. *псих. мед.* аффект, үз-үзен белмәү.

**АФФЕКТА'ЦИЯ** *ж.* — аффектация, артык кылану, кыланчыклык (сөйләүдә һәм үзен тотуда).

**АФФЕКТИ'ВНЫЙ** — 1. ярсулы; кызып, ярсып эшләнгән; 2. *псих. мед.* аффектив, үзен-үзе белмәү... -ы; *аффективные явления* — аффектив күренешләр.

**А'ФФИКС** *м. лингв.* — аффикс (тамыр сүзгә ялганган кушымча, мәсәлән, эш+че, трактор+чы һ. б.).

**АФФИЛЬИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — берләштерү, кушу.

**АФФИНИ'РОВАТЬ** *сов. тех.* — кушылмалардан чистарту (металлны).

**АФФИНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — кушылмалардан чистартылу (металл турында).

**АФФИРМА'ЦИЯ** *ж.* — аффирмация, раслау.

**АФФРИКА'Т** *м.*, **АФФРИКА'ТА** *ж. лингв.* — аффрикат (ике авазның кушылуыннан барлыкка килгән аваз, мәсәлән, т+с тан килеп чыккан ц).

**АХ** *межд.* — ах! әх! аһ! ух!

**А'ХАНЬЕ** *ср.* — ах-вах, ай-вай килү.

**А'ХАТЬ** *несов.* — ахылдау, ах-вах килү; *(от удивления)* таңга калу, искитү, гаҗәпләнү.

**АХИЛЛЕ'СОВА ПЯТА'** — кешенең йомшак ягы.

**АХИНЕ'Я** *ж. мн.* нет — мәгънәсез сүз, буш сүз, сафсата.

**А'ХНУТЬ** I *сов.* — шап итеп сугу; *ахнуть по спине* — аркасына шап итеп сугу. ◇ **Давай ахнем в лес** — әйдә, урманга сыздык.

**А'ХНУТЬ** II *сов.* — „әһ" дию, „ах" дип кую.

**А'ХОВЫЙ** — 1. *(плохого качества)* начар, яраксыз (товар); 2. *разг. простореч. (отчаянный)* тәвәккәл; *аховый парень* — тәвәккәл егет. ◇ **Дело аховое** — эш харап.

**АХТИ'** *межд.*— әй! кара син аны; *ахти, какой позор* — әй, нинди хурлык; *ахти, какой хитрый* — кара син аны, нинди хәйләкәр. ◇ **Не ахти какой** *(разг.)* — әллә кем түгел, әллә нинди түгел, искитәрлек түгел.

**АШУ'Г** *м.*— ашуг (Кавказ халыкларында халык шагыйре).

**АЭРОДИНА'МИКА** *ж. мн.* нет, *физ.*— аэродинамика (каты җисемнәр хәрәкәте вакытында һаваның аларга каршылык күрсәтүен тикшерә торган фән).

**АЭРОДИНАМИ'ЧЕСКИЙ** — аэродинамика ... -ы; аэродинамик; *аэродинамический институт* — аэродинамика институты.

**АЭРОДРО'М** *м. ав.*— аэродром (самолётлар, планерлар тора торган, очып китә торган, төшә торган һәм шулай ук ремонт ясала торган урын).

**АЭРОДРО'МНЫЙ** — аэродром ... -ы; *аэродромная площадка*—аэродром мәйданы.

**АЭРОКЛУ'Б** *м. ав.*— аэроклуб (авиация эшләрен өйрәнүчеләр клубы; анда ирекле рәвештә йөреп самолётта очарга өйрәнәләр).

**АЭРОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *физ.* — аэрологик, аэрология ... -ы; *аэрологическая наука* — аэрология фәне.

**АЭРОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *физ.*— аэрология (атмосфераның югары катлауларындагы процессларны өйрәнә торган фән).

**АЭРОМАЯ'К** *м. ав.*— аэромаяк (лётчикларга юлны чамалау өчен куела торган якты маяк).

**АЭРОНАВИГА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *ав.*— аэронавигация (аэроплан, дирижабльләрне карта, компас, радио һ. б. ярдәмендә билгеләнгән юл буенча йөртү фәне).

**АЭРОНА'ВТ** *м.*— аэронавт, һавада очучы кеше.

**АЭРОНА'ВТИКА** *ж. мн.* нет — аэронавтика (очу сәнгате һәм һавада очу турындагы фән).

**АЭРОПЛА'Н** *м.*— аэроплан, самолёт.

**АЭРОПЛА'ННЫЙ**—аэроплан ... -ы; *аэропланные части* — аэроплан частьлары.

**АЭРОПО'РТ** *м. ав.*— аэропорт (**1.** зур аэродром; **2.** күп һава юллары очраша торган пункт).

**АЭРОПО'ЧТА** *ж.*— аэропочта, һава почтасы (аэроплан белән җибәрелә торган почта).

**АЭРОСА'НИ** *ед.* нет — аэрочана (мотор ярдәмендә эшли торган пропеллерлы чана).

**АЭРОСЕ'В** *м. с.-х.*— аэропланнан чәчү (мәсәлән, ашлыкны), аэрочәчү.

**АЭРОСТА'Т** *м. ав.*— аэростат, һава шары (һавадан җиңелрәк очу аппараты).

**АЭРОСТА'ТИКА** *ж. мн.* нет — аэростатика (газларның тигезләнеше (равновесие) турындагы фән).

**АЭРОСЪЁМКА** — к. аэрофотосъёмка.

**АЭРОТРА'НСПОРТ** *м.*— аэротранспорт, һава транспорты.

**АЭРОФОТОАППАРА'Т** *м.*— аэрофотоаппарат (аэропланнан рәсем төшерә торган аппарат).

**АЭРОФОТОГРА'ФИЯ** *ж.*— аэрофотография (**1.** җир өсте рәсемен самолёттан, аэростаттан, дирижабльдән фотоаппарат белән төшереп алу; **2.** шундый юл белән алынган рәсем).

**АЭРОФОТОСНИ'МОК** *м.*— аэрофоторәсем (аэропланнан төшереп алынган рәсем).

**АЭРОФОТОСЪЁМКА** *ж.*— к. аэрофотография.

**АЯ'КСЫ** — аякслар (борынгы грек мифологиясендә бергәләп батырлыклар күрсәткән ике батыр, каһарман). ◇ **Два аякса** — аерылмас ике дус, агылый белән тагылый.

# Б

**Б** — к. бы.

**БА** *межд. разг.*— бәй, абау, һәй; *ба! ты откуда?* — бәй! син кайдан?

**БА'БА** I ж.— **1.** *устар. (замужняя крестьянка)* хатын, авыл хатыны (ирдәге); **2.** *устар. простореч. (жена)* хатын (ы, м, н); **3.** *фам. (женщина)* хатын-кыз (гомумән); **4.** *(старуха)* карчык, әби; *жили-были дед да баба* — борын-борын заманда булган ди бер карт белән карчык; **5.** *презр. (о слабохарактерном мужчине)* куркак, кыюсыз, тәвәккәлсез, вакчыл (ир кеше турында). ◇ **Бой-баба** — кыю, уңган хатын. **Каменная баба** — торатаtotal. **Снежная баба** — кар бабай.

**БА'БА** II *ж. тех.*— төйгеч, саплы бүкән, субай тукмагы (асылынмалы авыр тукмак).

**БА'БА** III *ж. кулин.*— озынча кулич, пасха күмәче (пирожныйның бер төре).

**БАБА'Х** *межд.* — шап! (шап итеп төште, егылды), гөрс!

**БАБА'ХАТЬ** *несов.*, **БАБА'ХНУТЬ** *сов. разг.*— **1.** кундыру, тондыру, каты сугу, шапылдату; **2.** гөрселдәү, шартлау.

**БАБА'ХНУТЬСЯ** *сов.*— шап итеп бәрелү, төшү, егылу, аву.

**БАБА'ШКА** *ж.*—**1.** *тип.* бабашка (типографиядә хәреф җыйганда буш урыннарны тутыру өчен кулланыла торган шакмак); **2.** *рыболов.* җылым-ятьмә калкавычы.

**Б'АБА-ЯГА'** *ж. миф.*— убырлы карчык.

**БАБЁНКА** *ж. разг.' фам.*— үткен хатын, чая хатын.

**БА'БИЙ** *разг.*— хатын-кыз ... -ы, хатын-кызлар ... -ы; *бабье дело* — хатын-кыз эше. ◇ **Бабье лето** — әбиләр чуагы, карчыклар җәе, карчыклар җылысы (көз башында атна-ун көнлек җылы вакыт). **Бабьи разговоры** — хатын-кыз сүзе, гайбәт, юк-бар сүз.

**БА'БКА** I *ж.*—**1.** *разг. (бабушка)* әби, әбкәй, дәү әни; **2.** *(старуха)* карчык. ◇ **Повивальная бабка** *устар.*— кендек әбисе.

**БА'БКА** II *ж.*— 1. *анат.* кузна сөяге, ашык сөяге; бәкәл (атныкы); 2. *(для игры)* чәмәй; кузна, бакай; *играть в бабки* — кузна уйнау, бакай уйнау; 3. *тех.* кыскыч (токарный станокта эшкәртелә торган әйберне кысу өчен).

**БА'БКА** III *ж. обл.*— сослан, бәбкә (көлтәләр өеме).

**БА'БНИК** *м. разг.*— хатын-кызлар белән чуалучан кеше, себерке.

**БА'БНИЧАТЬ** *несов.* — 1. хатын-кызлар артыннан йөрү; 2. әбилек итү, им-том белән шөгыльләнү.

**БА'БОЧКА** I ж. — күбәләк.

**БА'БОЧКА** II *ж. ласк. просторечь.*— чибәр хатын, сөйкемле яшь хатын.

**БАБУ'СЯ** *ж.*— әбекәй, дәү әни.

**БА'БУШКА** *ж.* 1. *(мать отца или матери)* әби, дәү әни; 2. *(обращение к старой женщине)* әби. ◇ **Бабушка надвое сказала** *разг.*— икеле, билгеле түгел; я булыр, я юк. **Бабушкин внучек**— әбисенең малае, иркә бала. **Вот тебе, бабушка, и Юрьев день!**—менә сиңа кирәк булса! менә сиңа нәрсә килеп чыкты!

**БАБЬЁ** *собир. презрит.* — хатыннар, җыен хатын-кыз(лар).

**БАГА'Ж** *м. мн.* нет —1. багаж, йөк (пассажирларның үзләре белән алып бара торган йөкләре; багаж белән җибәрә торган йөкләре); 2. *перен. (эрудиция)* багаж, белем хәзинәсе, белемнәр запасы (аерым кешенең белемнәр запасы турында).

**БАГА'ЖНИК** *м.*— багажник (велосипедта, мотоциклда, автомобильдә йөк куеп йөртү өчен ясалган урын).

**БАГА'ЖНЫЙ** —1. багаж ... -ы; *багажный вагон* — багаж вагоны; 2. *в знач. сущ.* багажчы (багажлар белән эш итүче хезмәткәр).

**БАГЕ'Т** *м.*— багет (картина, портрет рамалары һәм кәрнизләр ясау өчен кулланыла торган бер ягы бизәкле тар планка).

**БАГЕ'ТНЫЙ, БАГЕ'ТОВЫЙ**— багет ... -ы, багет..., багет ясый торган; багеттан ясалган; *багетная мастерская* — багет мастерское; *багетная рама* — багет рама.

**БАГЕ'ТЧИК** *м.*, **БАГЕ'ТЧИЦА** *ж.*— багетчы, багет ясаучы.

**БАГО'Р** *м.* — багор (озын агач саплы тимер ыргак).

**БАГО'РНЫЙ** — багор... -ы; *багорный крюк* — багор ыргагы.

**БАГО'РЩИК** *м.*— багорчы (ишкәндә, балык тотканда, сал агызганда багор белән эш итүче).

**БАГРЕ'Ц** *м. мн.* нет — 1. бурлат төс, куе кызыл буяу; 2. *устар.* бурлат тукыма.

**БАГРЕЦЫ'** *мн.*— төньяк балкышы.

**БА'ГРИТЬ** *несов.*—1. багор белән чыгару; 2. *перен. просторечь. вульг.* чәлү, чәлдерү, эләктерү (урлау).

**БАГРИ'ТЬ** *несов. книж.-поэт.*— кызыллау, кызылга ману, кызарту; бурлат төскә кертү, куе кызылга буяу.

**БАГРОВЕ'ТЬ** *несов.*— 1. кызару, кызыллану, куе күгелҗем кызыл төскә керү, шәфәкъ кызыллыгы керү; 2. кызарыну, бүртенү, күгәренү (ачу килүдән); кызару (оялудан).

**БАГРОВИ'ЩЕ** *ср.*— багор сабы.

**БАГРО'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — куе кызыллык, кучкыл кызыллык.

**БАГРО'ВЫЙ** — куе кызыл, кучкыл кызыл, кансу кызыл.

**БАГРЯНЕ'ТЬ** *несов.*— кызарып күренү, кызарып тору, алсуланып тору.

**БАГРЯ'НЕЦ** *м. мн.* нет — куе кызыл төс.

**БАГРЯ'НИСТЫЙ** — кызгылт, алсу.

**БАГРЯНИ'ТЬ** *несов.*— куе кызыл төскә ману (буяу).

**БАГРЯНИ'ЦА** *ж. устар.*— япанча (борынгы заманда куе кызыл материядән тегелгән патшалар киеме).

**БАГРЯ'НЫЙ** — кып-кызыл, җете кызыл, ачык (куе) кызыл.

**БАГУ'ЛЬНИК** *м. бот.*— сазанак (агулы үлән.)

**БАДА'Н** *м. бот.*— бадан, монгол чәе, чагыр.

**БАДЕ'ЕЧНЫЙ** — кое чиләге ... -ы; *бадеечное донышко* — кое чиләге төбе.

**БАДЕ'ЙКА** *ж.*— кечкенә кое чиләге.

**БАДЕ'ЙЩИК** *м.*— бадейщик (шахтада бадьялар тутырып торучы эшче).

**БАДЬЯ'** *ж.*— бадья; агач чиләк, кое чиләге; шахта чиләге.

**БАЗ** *м.* — терлек абзары.

**БА'ЗА** *ж.*—1.*только ед.* база, нигез, нигез ташы, төп; *материальная база* — материаль база, материаль нигез; 2. база, чыганак; *сырьевая база* — чимал базасы (чыганагы); 3. база; *товарная база* — товар базасы; *авиационная база* — авиация базасы; *туристская база* — туристлар базасы; 4. *архит.* база, нигез; *база колонны* — колонна базасы (нигезе). ◇ **Артикуляционная база** — артикуляция базасы (сөйләгәндә сөйләү органнарының торышы һәм хәрәкәтләре системасы).

**БАЗА'Р** *м.*—1. базар; 2. *перен.* базар, гауга, шау-шу. ◇ **Птичий базар** — кошлар базары (диңгез буенда кошлар җыела торган урын). **Книжный базар** — китап базары (матбугат көне уңае белән китаплар сату өчен ачык һавада оештырыла торган базар).

**БАЗА'РИТЬ** *несов. просторечь.* — вактөяк белән сәүдә итү, алыш-биреш итү.

**БАЗА'РНЫЙ** —1. базар ... -ы; *базарная площадь* — базар мәйданы; 2. әдәпсез, урамча; *базарная ругань* — әдәпсез сүгенү, урамча сүгенү. ◇ **Базарная баба** *разг.*— базар хатыны, әдәпсез хатын (кычкырышырга яратучан хатын). **Базарная работа** — к. базарщина.

**БАЗА'РЩИНА** — начар ясалган әйбер.

**БАЗИЛИ'К** *м. бот.* — рәйхан, базилик (зәңгәр чәчәкле, хуш исле гөл).

**БАЗИЛИ'КОВЫЙ**—рәйхан ... -ы; *базиликовое масло* — рәйхан мае.

**БАЗИ'РОВАТЬ** *несов.*— нигезләү, дәлилләү.

**БАЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов.*— таяну, нигезләнү (берәр дәлилгә, нигезгә таянып эш итү).

**БА'ЗИС** *м.*—1. базис (а. *филос. эк.* җәмгыять үсешенең билгеле бер этабында җәмгыятьнең экономик строе; *в Советском Союзе ликвидирован старый, капиталистический базис и построен новый, социалистический базис* — Советлар Союзында иске, капиталистик базис бетерелде, яңа, социалистик базис төзелде; б. *геодез.* төгәл үлчәнгән төп линия; в. кристаллик җисемнәр яссылыгының берсе); 2. нигез, төп.

**БА'ЗИСНЫЙ** — базис ..., база булып хезмәт итә торган; база ... -ы; *базисный прибор* — базис прибор; *базисный склад*—база склады.

**БАЙ-БАЙ, БА'ИНЬКИ** — бәй-бәй; бәүбәү, бәлли бәү; *пора бай-бай* — бәү-бәү итәргә (йокларга) вакыт.

**БАЙБА'К** *м*—1. *зоол.* байбак, суер (дала җәнлеге); 2. *перен.* ялкау, авыр гәүдәле кеше.

**БАЙБА'ЧИЙ** — байбак ... -ы, суер... -ы; *байбачья нора* — байбак өне.

**БАЙДА'К** *м. устар. обл.*— байдак (уртача зурлыктагы көймә).

**БАЙДА'ЧНИК** *м.*— байдакчы.

**БАЙДА'РА** *ж.*— зур йөк көймәсе.

**БАЙДА'РКА** *ж. спорт.* — каек, [байдарка.

**БА'ЙКА** I *ж. мн.* нет, *текст.*— байка (тукыма).

**БА'ЙКА** II *ж. разг. обл.* — кыска әкият, кыска мәсәл.

**БА'ЙКОВЫЙ** — байка ...; *байковое одеяло* — байка одеял.

**БАЙРОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — байронизм, байрончылык (1. әдәбиятта романтик агым; 2. *перен.* күңел төшенкелеге, өметсезлек, җәмгыятьне санга сукмау һәм үз-үзенә бикләнү). ◇ **Напустить на себя байронизм**— өметсезлеккә төшү, җәмгыятькә нәфрәт белән карау.

**БАЙРОНИ'ЧЕСКИЙ** — байрончыл, байронизм белән сугарылган; *байроническая поэзия* — байрончыл поэзия.

**БА'ЙХОВЫЙ: байховый чай** — арзанлы кара чәй.

**БАК** *м.*— бак; *бензиновый бак* — бензин багы.

**БАКАЛЕ'ЙНЫЙ** — бакалея ... -ы; *бакалейные товары* — бакалея товарлары.

**БАКАЛЕ'ЙЩИК** *м.*— бакалеячы (бакалея товарлары сатучы; бакалея товарлары сәүдәгәре).

**БАКАЛЕ'Я** *ж. мн.* нет— бакалея (төрле ашамлык товарлары, мәсәлән, чәй, шикәр, он, ярма, борыч, тоз һ. б.).

**БА'КЕН** I *м. мор.*— бакен, маяк (елганың сай урынын күрсәтү өчен куела).

**БА'КЕН** II *м.*— чигә сакалы.

**БАКЕНБА'РД** *м.*, **БАКЕНБА'РДА** *ж.*— к. бакен II.

**БА'КЕНЩИК** *м.*— бакенчы, маякчы (елгада).

**БА'КИ** *мн. простореч. устар.*— к. бакен II.

**БАКЛА'ГА** *ж.*— баклага, фляга (яссы калай савыт).

**БАКЛАЖА'Н** *м. бот.*— баклажан, бадымҗан (яшелчә).

**БАКЛАЖА'ННЫЙ** — баклажан ... -ы; *баклажанная икра* — баклажан икрасы.

**БАКЛА'ЖКА** *ж.*— к. баклага.

**БАКЛА'Н** *м.*— баклан, диңгез козгыны.

**БАКЛУ'ША** *ж. обл.*—1. баклуша (савыт-саба ясар өчен хәзерләнгән түмәр); 2. күгелҗем акчарлак.

**БАКЛУ'ШИ: бить баклуши** *разг.*— тырай тибү, сөрән сугу (эшсез йөрү).

**БАКЛУ'ШНИЧАТЬ** *несов.*— к. бить баклуши.

**БАКТЕРИА'ЛЬНЫЙ**—*к.* бактерийный.

**БАКТЕРИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— бактерияләштерү, бактерияләр тәэсиренә кую.

**БАКТЕРИЗОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— бактерияләштерелү, бактерияләр тәэсиренә куелу.

**БАКТЕРИ'ЙНЫЙ, БАКТЕРИА'ЛЬНЫЙ** — бактериаль, бактерияле; *бактериальное (бактерийное) удобрение* — бактериаль ашлама, бактерияле ашлама.

**БАКТЕРИО'ЛОГ** *м.*— бактериолог (бактериология белгече).

**БАКТЕРИОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — бактериологик, бактериология ... -ы; *бактериологический институт* — бактериология институты; *бактериологический анализ* — бактериологик анализ.

**БАКТЕРИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — бактериология (бактерияләр, микроблар турындагы фән).

**БАКТЕ'РИЯ** *ж.*— бактерия, микроб (бер күзәнәкле микроскопик тере организм).

**БАКТРИА'Н** *м.*— бактриан (ике өркәчле дөя).

**БАКШИ'Ш** *м.*— чәйлек, сыйлык, бәхшиш; взятка, ришвәт.

**БАЛ** *м.*— бал (биюле, танецлы кичә, мәҗлес). ◇ **Кончен бал**—бетте-китте, вәссәлам.

**БАЛАБА'Н** *м. зоол.*— этәлге (кош).

**БАЛАБО'ЛИТЬ, БАЛАБО'НИТЬ, БАЛАБО'ШИТЬ** *несов. простореч.*—1. лыгырдау, сафсата сату, юк-бар сөйләү, гайбәт сату; 2. эшсез йөрү, юкны бушка аудару, тырай тибү.

**БАЛАБО'ЛКА** *м.* и *ж. простореч.* 1. бушбугаз, лыгырд(ав)ык; 2. *ж.* шалтыравык (уенчык), шөлдер (кечкенә кыңгырау).

**БАЛАБО'НЩИК** *м.*, **БАЛАБО'НЩИЦА** *ж.*— лыгырдык, бушбугаз, такылдык.

**БАЛАБО'ШКА** *м.* и *ж.*— к. балаболка 1.

**БАЛАГА'Н** *м.*— балаган (1. элекке заманнарда ярминкәләрдә күрсәтелә торган уен, тамаша; кәмит; 2. шул уенны күрсәтү өчен тактадан ясалган җиңелчә генә бина; 3. ярминкәдә сату итү өчен вакытлыча ясалган агач будка; 4. *пренебр.* художество ягыннан түбән театр тамашасы; 5. рәтечираты булмаган эш, житди булмаган эш; 6. *пренебр.* начар өй, алачык, чатыр). ◇ **Что**

за балаган!— нәрсә сез монда кәмит корып утырасыз! бу нинди тамаша бу!

**БАЛАГА'НИТЬ, БАЛАГА'ННИЧАТЬ** *несов. разг.*— кылану, шамакайлану, көлдерергә маташып кылану.

**БАЛАГА'ННЫЙ** — кәмит ... -ы; *балаганный шут* — кәмит мәзәкчесе.

**БАЛАГА'НЩИК** *м.*, **БАЛАГА'НЩИЦА** *ж.*—1. балаганчы, балаган хуҗасы; 2. кәмит мәзәкчесе; кыланучы, шамакайланучы.

**БАЛАГА'НЩИНА** *ж.*— шамакайлык, кыланчыклык.

**БАЛАГУ'Р** *м.*, **БАЛАГУ'РКА** *ж. разг.*— мәзәк(че) кеше, шаян; такылдык.

**БАЛАГУ'РИТЬ** *несов. разг.*— мәзәк сөйләү.

**БАЛАГУ'РНЫЙ** — шаян, мәзәкчән.

**БАЛАГУ'РСТВО** *ср. разг.*— мәзәк кору (тыңлаучыларны көлдерү өчен җыен юкбар сүзләр сөйләү).

**БАЛА'КАТЬ** *несов. обл.*— әңгәмә кору, сөйләшү, ләчтит сату.

**БАЛАЛА'ЕЧНИК** *м.*—1. балалайкада уйнаучы; 2. балалайка мастеры.

**БАЛАЛА'ЕЧНЫЙ** — балалайка ... -ы; *балалаечная струна* — балалайка кылы.

**БАЛАЛА'ЙКА** *ж.*— балалайка (музыка коралы).

**БАЛАМУ'Т** *м.*, **БАЛАМУ'ТКА** *ж.*— болгатып йөрүче, коткычы, әләкче, баламут; тәртипне бозучы.

**БАЛАМУ'ТИТЬ** *несов.*—1. *(вызывать беспокойство)* юкка борчу, гайбәт таратып тәртипсезлек кертү; ара бозу, дөнья бозу; 2. *(мутить)* болганчыкландыру, болгату (суны).

**БАЛАНС** I *м.*— баланс, тигезләмә (1. *бухг.* керем һәм чыгым суммаларын эченә алган ведомость; 2. *экон.* чит илләрдән кертелә торган товарлар белән чит илләргә чыгарыла торган товарлар арасындагы мөнәсәбәт; *активный баланс* — актив баланс (чыгарылган товарларның кертелгән товарлардан күбрәк булуы); *пассивный баланс*— пассив баланс (кертелгән товарларның чыгарылган товарлардан күбрәк булуы).

**БАЛАНС** II *м. мн.* нет — баланс (целлюлоза эшләп чыгара торган заводлар өчен хәзерләнгән агач материалы).

**БАЛАНСЁР** *м.*, **БАЛАНСЁРКА** *ж.*— балансёр (аркан өстендә йөрүче, биюче акробат).

**БАЛАНСИ'Р** *м.* — балансир (1. кесә һәм дингез сәгатьләрендә маятник хезмәтен үти торган регулятор; 2. үлчәүләрдә, үлчәү приборларында, насосларда һ. б. авырлыкны һәм хәрәкәтне механизмның аерым буыннарына тапшыру көянтәсе).

**БАЛАНСИ'РОВАТЬ** *несов.*— 1. тигезлек саклау (тән хәрәкәтләре ярдәме белән); 2. тигезлек хәленә китерү; 3. *бухг.* баланс чыгару, баланс ясау.

**БАЛАНСИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— баланс чыгарылу, баланс ясалу.

**БАЛА'НСОВЫЙ** — баланс...-ы; *балансовый отчёт* — баланс отчёты.

**БАЛАХО'Н** *м.*— балахон (1. киң, озын халат; 2. киң, озын итеп начар тегелгән кием).

**БАЛАХО'ННИК** *м. устар. обл.*— йолкыш, өтек (алама киенгән кеше).

**БАЛБЕ'С** *м. разг. бран.*— аңгыра, күсәк, ҫантый, сөрхәнтәй.

**БАЛБЕ'СНИЧАТЬ** *несов. разг.*— юкны бушка аударып йөрү, бушка вакыт үткәрү, тырай тибү.

**БАЛДА'** *ж.* — 1. авыр чүкеч (таш вату өчен), төйгеч; 2. күсәк очындагы чукмар; 3. *перен.* аңгыра, тинтәк, күсәк, күзле бүкән.

**БАЛДАХИ'Н** *м.*— балдахин (зиннәтле чатыр).

**БАЛЕРИ'НА** *ж.*— балерина (балетта биюче артистка).

**БАЛЕ'Т** *м.*— балет (1. биюдән һәм тән хәрәкәтләреннән гыйбарәт булган музыкалы театр уены; 2. балет өчен язылган музыкаль әсәр).

**БАЛЕТМЕ'ЙСТЕР** *м.*— балетмейстер (балетта биюләр җитәкчесе; балет биюләренә өйрәтүче).

**БАЛЕТМЕ'ЙСТЕРСКИЙ** — балетмейстер...-ы, балетмейстерлык...-ы; *балетмейстерская должность* — балетмейстерлык хезмәте.

**БАЛЕ'ТНЫЙ** — балет...-ы; *балетное искусство* — балет сәнгате.

**БАЛЕТОМА'Н** *м.* — балетоман, балет яратучы, балет һәвәскәре.

**БАЛЕТОМА'НИЯ** *ж. мн.* нет — балетомания (балет белән чиктән тыш мавыгу).

**БАЛЕТОМА'НКА** *ж.*— балетоманка, балет яратучы, балет һәвәскәре (хатын-кыз).

**БА'ЛКА** I *ж.*— 1. *(бревно)* матчалык, өрлеклек (дүрт кырлы бүрәнә); 2. *(сама балка)* өрлек, матча.

**БА'ЛКА** II *ж. обл.*— озын чокыр, сыза, коры үзән (су казыган иңсу җир).

**БАЛКО'ННЫЙ** — балкон...-ы; *балконные перила* — балкон култыксалары.

**БАЛЛ** *м.*— 1. балл (берәр күренешнең, мәсәлән, җилнең, җир тетрәүнең, су дулкынлануының, уңышның дәрәҗәсен яки интенсивлыгын үлчәү берәмлеге); 2. балл, бәя, билге (укучыларның белемен һәм тәртибен бәяләү өчен куела торган билге, отметка); 3. балл, шар (тавыш бирү өчен кулланыла торган шар).

**БАЛЛА'ДА** *ж.*— баллада (1. легенда яки әкият темасына язылган сюжетлы шигырь; 2. *муз.* музыка әсәрләренең бер төре).

**БАЛЛА'ДНЫЙ** — баллада...-ы; *балладный сюжет* — баллада сюжеты.

**БАЛЛА'СТ** *м. мн.* нет — балласт (1. салмаклыкны саклау өчен корабльләргә, аэростатларга салынган йөк; 2. тимер юл шпалларын күмеп ныгыту өчен салынган вак таш, ком; 3. *перен.* артык йөк, имгәк, билгеле бер эш өчен файдасыз кеше).

**БАЛЛАСТИ'РОВАТЬ** *несов. ж.-д.*— балласт белән күмү (тимер юлны).

**БАЛЛАСТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. ж.-д.*— балласт белән күмелү.

**БАЛЛА'СТНЫЙ, БАЛЛА'СТОВЫЙ** *спец.*— балласт...-ы; *балластный поезд* — балласт поезды (балласт ташучы поезд).

**БАЛЛИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — баллистика (туп снарядларының көпшә эчендә һәм

аннан чыкканнан соң хәрәкәт итү (очу) законнарын өйрәнә торган фән).

**БАЛЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** — баллистик, баллистика...-ы; *баллистический закон* — баллистика законы.

**БАЛЛО'Н** *м.* — баллон (1. тар муенлы шарсыман пыяла савыт; 2. газлар һәм кислоталар саклау савыты; 3. һава тутырылган шин (автомобиль көпчәгендә); 4. аэростатның газ үткәрми торган тышы, кабыгы).

**БАЛЛО'ННЫЙ** — баллон...-ы; *баллонная мастерская* — баллон мастерское.

**БАЛЛОТИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. сайлау; 2. тавыш бирү; 3. тавышка кую; *баллотировать вопрос* — мәсьәләне тавышка кую.

**БАЛЛОТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. сайлану; 2. тавышка куелу.

**БАЛЛОТИРО'ВКА** *ж.* — 1. тавыш бирү; 2. тавышка кую.

**БАЛЛОТИРО'ВОЧНЫЙ** — баллотировка...-ы; *баллотировочный ящик* — баллотировка ящигы.

**БА'ЛЛЬНЫЙ: баллъная система** — балл системасы, балл куеп бәяләү системасы; **пятибалльная система** — биш баллы система.

**БАЛО'ВАННЫЙ** — иркә, иркәләп бозылган.

**БАЛОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *(изнеживать)* иркәләп бозу, ирек кую, ирек бирү, чиктән тыш мактап бозу; 2. *(баловаться)* шаяру, шуклану; 3. *обл. (разбойничать)* талау, юл басу, шаяру.

**БАЛОВА'ТЬСЯ** I *несов. разг.* — 1. *(шалить)* шаяру, шуклану; азу; 2. шаярып эшләү; *балуюсь табаком* — шаярып тәмәке тартам.

**БАЛОВА'ТЬСЯ** II *несов.* — иркәләп бозылу.

**БА'ЛОВЕНЬ** *м.* — 1. иркә, назлы; 2. шаян, шук.

**БАЛОВНИ'К** *м.* — шаян, шук.

**БАЛОВНИ'ЦА** *ж.* — 1. иркә, назлы кыз; 2. шаян, шук кыз.

**БАЛОВНО'Й** *простореч.* — шаян, шук.

**БАЛОВСТВО'** *ср. мн.* нет — 1. иркәләү, назлау; 2. шаянлык, шуклык; азыну.

**БАЛТИ'ЙСКИЙ** — Балтик...-ы; *Балтийское море* — Балтик диңгезе.

**БАЛТИ'ЕЦ** *м.* — балтиец, балтикчы (Балтик флотында хезмәт итүче).

**БАЛЫ'К** *м.* — 1. кызыл балыкның какланган сырт ите; 2. кызыл балык.

**БАЛЫКО'ВЫЙ** — кызыл балык...-ы; *балыковая икра* — кызыл балык икрасы.

**БАЛЬЗА'М** *м.* — 1. бальзам, бәлсән (эфир майлары кушылган ярым сыек һәм исле сумала; техникада һәм медицинада кулланыла); 2. *перен. устар. поэт.* куаныч, тынычлык.

**БАЛЬЗАМИ'Н** *м. бот.* — бальзамин, бохар кынасы, кына гөле.

**БАЛЬЗАМИ'ННЫЙ, БАЛЬЗАМИ'НОВЫЙ** — бальзамин...-ы; *бальзаминный листок* — бальзамин яфрагы.

**БАЛЬЗАМИ'РОВАТЬ** *несов.* — бәлзәмләү (мәетләрне черүдән саклау өчен).

**БАЛЬЗАМИРО'ВЩИК** *м.* — бәлзәмләүче.

**БАЛЬЗАМИ'ЧЕСКИЙ, БАЛЬЗА'МНЫЙ, БАЛЬЗА'МОВЫЙ** — бәлзәм...-ы; *бальзамовый запах* — бәлзәм исе.

**БАЛЬНЕОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — бальнеология (минераль чишмәләрне, суларны, ләмнәрне һәм алар белән дәвалау методларын өйрәнә торган фән).

**БА'ЛЬНИК** *м. дореволю.* — бальник (укучыларның отметкалары куелган ведомость).

**БА'ЛЬНЫЙ** — бал...-ы; *бальный костюм* — бал костюмы.

**БАЛЮСТРА'ДА** *ж.* — балюстрада, култыкса (балконнарда, баскычларда).

**БАЛЯ'СИНА** *ж.* — текмә, баганачык (култыксада).

**БАЛЯ'СНИЧАТЬ** *несов. обл.* — юк-барны сөйләп вакыт үткәрү, ләчтит сату.

**БАЛЯ'СЫ** — к. балясина. ◇ **Балясы точить** *простореч.* — к. балясничать.

**БАМБУ'К** *м. бот.* — бамбук, һинд камышы (агачсыман каты камыш).

**БАМБУ'КОВЫЙ** — бамбук...-ы, бамбук..., бамбуктан ясалган; *бамбуковый лист* — бамбук яфрагы; *бамбуковая трость* — бамбук таяк. ◇ **Бамбуковое положение** — аптыраш хәл, кыен хәл.

**БАНА'ЛЬНОСТЬ** *ж* — искергән сүз, күп чәйнәлгән сүз, искергән фикер.

**БАНА'ЛЬНЫЙ** — искергән, таушалган, күп чәйнәлгән (сүз, фикер).

**БАНА'Н** *м. бот.* — банан (1. пальмасыман тропик үсемлек; 2. аның җимеше).

**БАНА'НОВЫЙ** — банан...-ы; *банановый лист* — банан яфрагы.

**БА'НДА** *ж.* — банда (җинаятьчеләр, контрреволюционерлар, диверсантлар, үтерүчеләр шайкасы).

**БАНДА'Ж** *м.* — бандаж (1. гәүдәнең берәр органын нормаль торышта саклау өчен кулланыла торган махсус бәйләвеч; 2. *тех.* вагон яки паровоз көпчәгенең корыч тугымы, шины).

**БАНДАЖИ'СТ** *м.*, **БАНДАЖИ'СТКА** *ж.* — бандажчы, бандажлар тегүче.

**БАНДА'ЖНИК** *м.* — 1. к. бандажист; 2. бандажник (паровоз яки вагон көпчәгенә корыч тугым утыртучы һәм аны салдыручы).

**БАНДА'ЖНЫЙ** — бандаж...-ы; *бандажная мастерская* — бандаж мастерское.

**БАНДЕРО'ЛЬ** *ж.* — бандероль (1. китапларны, документларны почта белән җибәрү өчен кулланыла торган киң кәгазь төргеч; 2. шундый төргечтә почта белән җибәрелгән әйбер; 3. акцизның яки пошлинаның түләнгәнлеген күрсәтү өчен товарга ябыштырылган ярлык).

**БАНДЕРО'ЛЬНЫЙ** — бандерольле, бандероль белән...; *бандерольное отправление* — бандероль белән җибәрелгән әйбер.

**БАНДИ'Т** *м.* — бандит, юлбасар, баскынчы, юл кисүче.

**БАНДИТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — бандитлык, юлбасарлык, талау.

**БАНДИ'ТСКИЙ** — бандитлар...-ы; бандитларча...; *бандитская шайка* — бандитлар

шайкасы; *бандитское нападение* — бандитларча һөҗүм.

**БАНДУ'РА** *ж.*— бандура (Украина халкының кыллы музыка коралы).

**БАНДУРИ'СТ** *м.*— бандурачы.

**БАНК** *м.*— банк (төрле финанс операцияләре алып бара торган кредит учреждениесе).

**БА'НКА** I *ж.*— банка (1. пыяладан яки калайдан ясалган цилиндрик савыт; 2. *только мн. мед.* банка салу өчен кулланыла торган йомры төпле кечкенә стаканнар).

**БА'НКА** II *ж.*— сайлык (диңгездә).

**БАНКАБРО'Ш** *м. тех.*— банкаброш (җеп эрләү машинасы).

**БАНКАБРО'ШНИЦА** *ж.*— банкаброшница (банкаброшта эшләүче хатын-кыз).

**БАНКАБРО'ШНЫЙ** — банкаброш...-ы; *банкаброшные катушки* — банкаброш кәтүкләре.

**БАНКЕ'Т** *м.*— банкет (тантаналы сый мәҗлесе).

**БАНКИ'Р** *м.*— банкир (банк хуҗасы яки аның акционеры).

**БАНКИ'РСКИЙ** — банкир...-ы, банкирлар...-ы; *банкирская контора* — банкирлар конторасы.

**БАНКНО'Т** *м.*, **БАНКНО'ТА** *ж.*— банкнот (банк тарафыннан чыгарылган кәгазь акча).

**БА'НКОВСКИЙ, БА'НКОВЫЙ** — банк...-ы; *банковский служащий* — банк хезмәткәре. ◇ **Банковый билет** *фин. офиц.* — к. банкнот.

**БАНКРО'Т** *м.*— банкрот (1. бөлгән, шартлаган бай; 2. *перен.* идея ягыннан һәлакәткә очраган кеше, оешма, юнәлеш; өстенә йөкләнгән вазифаларны үти алмаган яки үтәргә көче җитмәгән кеше).

**БАНКРО'ТИТЬСЯ** *несов.*— 1. банкрот булу, шартлау, бөлү; 2. *перен.* идея ягыннан тулы һәлакәткә очрау, көчсез булып калу.

**БАНКРО'ТСТВО** *ср.*— 1. банкротлык, бөлү; 2. *перен.* идея ягыннан гаҗизлек, нигезсезлек, төпсезлек; тулы һәлакәткә очрау, җимерелү; *банкротство политики агрессоров* — агрессорлар политикасының җимерелүе.

**БА'ННИК** *м.*— банник, пумала (туп көпшәсен чистарту пумаласы).

**БА'ННЫЙ** — мунча...-ы; *банный веник* — мунча себеркесе. ◇ **Пристал как банный лист** — сагыз булдың инде; дегет пумаласы булдың инде; теш корты булдың инде; кырмавык кебек ябыштың инде.

**БАНТ** *м.*— бант (күбәләксыман итеп әлмәкләп бәйләнгән тасма, лента).

**БА'НТИК** *м.*— к. бант.

**БА'НЩИК** *м.*, **БА'НЩИЦА** *ж.*— мунчачы, мунча хезмәтчесе.

**БА'НЯ** *ж.*— 1. мунча; 2. *перен.* эсселек. ◇ **Задать баню** — орышу, кыздыру. **Кровавая баня** — канкоеш, суеш, үтереш.

**БАОБА'Б** *м.*— баобаб, маймыл агачы.

**БАР** I *м.*— бар, кечкенә ресторан.

**БАР** II *м.*— сайлык (елга тамакларында).

**БАР** III *м.*— бар (атмосфера басымын үлчәү берәмлеге).

**БАРАБА'Н** *м.*— барабан (1. музыка коралы; 2. *тех.* машиналарда һәм механизмнарда эче куыш цилиндр; 3. *анат.* урта колакның эчке куышы). ◇ **Барабан бильный** — сырлы барабан (молотилкада). **Барабан штифтовый** — тешле барабан (молотилкада).

**БАРАБА'НИТЬ** *несов.*— 1. барабан кагу, барабан сугу; 2. *перен.* такылдау, ашыгып сөйләү; 3. *перен. разг.* начар уйнау, дыңгырдату (музыка коралында).

**БАРАБА'ННЫЙ** — барабан...-ы; *барабанный звук* — барабан тавышы. ◇ **Барабанная перепонка** *анат.*— колак пәрдәсе.

**БАРАБА'НЩИК** *м.*— барабанчы, барабан кагучы.

**БАРА'К** *м.*— барак (1. вакытлы торак; 2. *спец.* больницаның аерым бер бүлеге, гадәттә йогышлы авырулар өчен булган бүлек).

**БАРА'Н** *м.*— 1. тәкә, сарык тәкәсе; 2. кыргый сарык; 3. *перен.* киребеткән, үҗәт; аңгыра, тинтәк.

**БАРА'НИЙ** — тәкә...-ы; *баранье копыто* — тәкә тоягы. ◇ **Согнуть в бараний рог** — буйсындыру, буйсынырга мәҗбүр итү, иен китерү.

**БАРА'НИНА** *ж. мн.* нет — сарык ите, куй ите.

**БАРА'НКА** I *ж.* — клиндер (ашамлык).

**БАРА'НКА** II *ж. простореч. шутл.* — баранка (автомобиль руленең тәгәрмәче).

**БАРА'НОК** *м.*— ике тоткалы ышкы.

**БАРА'НОЧНИК** *м.*, **БАРА'НОЧНИЦА** *ж.*— 1. клиндер пешерүче; 2. клиндер сатучы.

**БАРА'НЧИК** *м. бот.*— сөтлегән, мәче бөтнеге.

**БАРАХЛО'** *ср. мн.* нет, *простореч.*— 1. иске-москы, чүпрәк-чапрак, вак-төяк; 2. чүп-чар (яраксыз әйбер, начар әйбер); 3. *бран. вульг.* (*о человеке*) чүпрәк.

**БАРА'ХТАТЬСЯ** *несов.*— тыпырчыну, чабалану; көрмәкләшү.

**БАРА'ХТЫ: с бухты-барахты** — к. бухты-барахты.

**БАРА'ЧНЫЙ** — барак...-ы; *барачная система* — барак системасы.

**БАРА'ШЕК** *м.*— 1. сарык бәрәне; 2. илтер (иләнгән, эшкәртелгән бәрән тиресе); 3. *обл.* бекас (саз кошы); 4. ике колаклы гайка; 5. *перен.* юаш кеше, уҗым бозавы.

**БАРА'ШКИ** *только мн.* — 1. ак башлы дулкыннар, ак күбекле дулкыннар; 2. бөдрә болытлар (вак, ак болытлар).

**БАРА'ШКОВЫЙ** — илтер..., бәрән тиресеннән тегелгән; *барашковая шапка* — илтер бүрек, бәрән тиресеннән тегелгән бүрек.

**БАРА'ШКОМ** *нареч.*— вак бөдрәле итеп.

**БАРБАРИ'ЗМ** *м. устар.*— к. варваризм.

**БАРБАРИ'С** *м.*— барбарис (чәнечкеле куак һәм аның җимеше).

**БАРБАРИ'СОВЫЙ** — барбарис... -ы; *барбарисовое варенье* — барбарис вареньесы.

**БАРБО'С** *м.*— 1. барбос (йорт эте кушаматы); 2. *перен. разг.* тупас кеше.

**БАРБОТИ'Н** *м.* — барботин (1. художестволы керамика өчен фаянс камыры; 2. күпертеп эшләнгән һәм төрле төскә буялган, чәчәк һәм яфрак рәсемнәре белән бизәлгән ваза).

**БАРВИ'НОК** *м. бот.* — барвинок (мәңге яшел яфраклы үрмәле үсемлек).

**БАРВИ'НКОВЫЙ** — барвинок...-ы; *барвинковый лист* — барвинок яфрагы.

**БАРД** *м.* — бард (1. борынгы кельтларда шагыйрь яки җырчы; 2. *перен.* шагыйрь (гомумән).

**БАРДА'** *ж. мн.* нет — барда, куерык (спирт һәм сыра ясаганда кала торган түп).

**БАРЕ'Ж** *м. мн.* нет — бареж (йон тукыма).

**БАРЕ'ЖЕВЫЙ** — бареж... ; *барежевое платье* — бареж күлмәк.

**БАРЕЛЬЕ'Ф** *м. искус.* — барельеф (яссылык өстенә күпертеп ясалган скульптур рәсем).

**БАРЕЛЬЕ'ФНЫЙ** *искус.* — барельефлы.

**БАРЕ'ТКА** *ж. устар.* — хатын-кыз туфлие.

**БА'РЖА'** *ж.* — баржа.

**БАРЖЕВО'Й** — баржа...-ы, баржалар...-ы; *баржевая мачта* — баржа мачтасы.

**БА'РИЕВЫЙ** — барийлы; *бариевый полевой шпат* — барийлы кыр шпаты.

**БА'РИЙ** *м. мн.* нет, *хим.* — барий (көмешсыман соры йомшак металл).

**БА'РИН** *м. устар.* — 1. барин, алпавыт, бояр; 2. *простореч. доревол.* түрә, әфәнде, хуҗа; 3. *разг. неодобр.* аксөяк; эшлексез, тик ятучы, кеше җилкәсен кимерүче.

**БАРИСФЕ'РА** *ж.* — барисфера (җир шарының үзәк ядросы).

**БАРИ'Т** *м. мн.* нет — барит (авыр шпат; төрле төстәге минерал; промышленностьта һәм авыл хуҗалыгында киң кулланыла).

**БАРИТО'Н** *м.* — баритон (1. бас һәм тенор урталыгында ирләр тавышы; 2. шул тавыш белән җырлаучы; 3. тынлы музыка коралының бер төре).

**БАРИТОНА'ЛЬНЫЙ** — баритональ, баритонга якын; *баритональный тенор* — баритональ тенор.

**БАРИТО'ННЫЙ**, *разг.* **БАРИТО'НОВЫЙ** — баритон... -ы; *баритонная партия* — баритон партиясе.

**БАРИЦЕ'НТР** *м.* — барицентр (геометрик фигураның авырлык үзәге).

**БАРИЦЕНТРИ'ЧЕСКИЕ КООРДИНА'ТЫ** — барицентрик координаталар (яссылыкта ноктаның урынын билгели торган өч зурлык).

**БА'РИЧ** *м. разг. неодобр.* — 1. байбәтчә, барин баласы; 2. *перен.* аксөяк (иркәләп бозылган, назлы кеше).

**БАРИ'ЧЕСКИЙ** — барик (атмосфера басымына бәйләнешле).

**БА'РКА** *ж.* — барка (баржадан кечкенәрәк яссы төпле йөк көймәсе).

**БАРКАРО'ЛА** *ж.* — баркарола (Венеция көймәчеләренең җыры).

**БАРКА'С** *м.* — баркас (1. берничә пар ишкәкле зур каек, йөк көймәсе; 2. үзйөрешле кечкенә пароход; 3. күн производствосында кулланыла торган махсус бак).

**БАРКА'СНЫЙ** — баркас... -ы; *баркасная прислуга* — баркас командасы.

**БА'РМЫ** *истор.* — барма (борынгы Москва патшалары һәм князьләренең тантана вакытларында җилкәгә салып чыга торган киемнәре).

**БАРОГРА'ММА** *ж.* — барограмма (барограф язган кәкре сызма).

**БАРО'ГРАФ** *м.* — барограф (үзе яза торган барометр).

**БАРОКА'МЕРА** *ж.* — барокамера (сыек яки куе атмосфераны барлыкка китерү өчен җайланган бина).

**БАРО'ККО** *ср. нескл. искус.* — барокко (XVII—XVIII йөзләрдә Көнбатыш Европа сәнгатендә бер стиль).

**БАРО'МЕТР** *м.* — барометр (атмосфера басымын үлчәү приборы).

**БАРОМЕТРИ'ЧЕСКИЙ** — барометрик; *барометрический максимум* — барометрик максимум.

**БАРО'Н** *м. истор.* — барон (Көнбатыш Европада дворяннарның графтан түбәнрәк титулы).

**БАРОНЕ'ССА** *ж.* — баронесса (барон хатыны яки кызы).

**БАРОНЕ'Т** *м.* — баронет (Англиядә дворянлык титулы).

**БАРОСКО'П** *м.* — бароскоп (1. Архимед законын һава чолганышы шартларында демонстрацияләү приборы; 2. һава басымы үзгәрешләрен белү приборы).

**БАРОСТА'Т** *м.* — баростат (суыткыч камераларда, шкафларда кирәкле түбән температураны саклау өчен автоматик прибор).

**БА'РОЧНИК** *м.* — барка хуҗасы; баркада эшләүче эшче.

**БА'РОЧНЫЙ** — барка...-ы; *барочный якорь* — барка якоре.

**БАРО'ЧНЫЙ** *искус.* — барокко...-ы; *барочный стиль* — барокко стиле (артык зиннәтләнгән, күпертелгән, чачаклы-чуклы).

**БАРРА'Ж** *м.* — барраж (1. *ав.* самолётларның очуына тоткарлык ясау өчен һавада ясалган киртәләр; 2. *мор.* корабльләргә, су асты көймәләренә тоткарлык ясау өчен диңгездә куелган миналар).

**БАРРАЖИ'РОВАТЬ** *несов. спец.* — барражировать итү, һаваны күзәтеп йөрү (дошман самолётларын үткәрмәү өчен самолётларның билгеле бер районда һаваны күзәтеп йөрүләре).

**БАРРЕ'ЛЬ** *м.* — баррель (сыек һәм бөртекле әйберләр үлчәве).

**БАРРИКА'ДА** *ж.* — баррикада (1. урам сугышлары вакытында төрле әйберләрдән өеп ясалган ныгытма; 2. *перен.* юлдагы тоткарлык, киртә). ◇ По ту сторону баррикад — дошманнар лагерендә, дошманнар ягында.

**БАРРИКАДИ'РОВАТЬ** *несов.* — баррикадалау, баррикада белән бүлү.

**БАРРИКАДИ'РОВАТЬСЯ** *несов.* — баррикадалану, баррикада белән бүленү.

**БАРРИКА'ДНЫЙ** — баррикада...-ы; *баррикадный бой* — баррикада сугышы.

**БАРС** *м.* — барс, чуар юлбарыс.

**БА'РСКИЙ** — барин...-ы; бариннар...-ы; бариннарча...; *барская спесь* — барин тәкәбберлеге; *барские выходки* — бариннар кыланышы, бариннарча кыланыш. ◇ **Жить на барскую ногу** — бариннарча яшәү, байларча тору.

**БАРСОВИ'НА** *ж.*— 1. барс тиресе; 2. тимгел, тап (барс, юлбарыс һ. б. тиресендә).

**БА'РСОВЫЙ** — барс...-ы; *барсовая шкура* — барс тиресе.

**БА'РСТВЕННЫЙ** — эре, бариннарча...; *барственный вид* — эре кыяфәт, бариннарча кыяфәт.

**БА'РСТВО** *ср. мн.* нет — 1. дворяннар сословиесе; 2. *собир.* дворяннар, алпавытлар; 3. *разг.* (*изнеженность*) дворяннарча иркәлек, назлылык.

**БА'РСТВОВАТЬ** *несов.* — эшсез яшәү, башкалар җилкәсендә яшәү.

**БАРСУ'К** *м. зоол.* — бурсык.

**БАРСУКО'ВЫЙ, БАРСУ'ЧИЙ** — бурсык...-ы; *барсучья шкура* — бурсык тиресе.

**БАРХА'НЫ** *мн.* — барханнар (чүлләрдә ком өемнәре).

**БА'РХАТ** *м.*— бархат, хәтфә.

**БАРХАТИ'СТЫЙ** — 1. бархатсыман, хәтфәсыман, йомшак; 2. *перен.* (*о голосе*) нәфис, йомшак.

**БА'РХАТКА** *ж. разг.*— бархат тасма.

**БА'РХАТНЫЙ** — 1. бархат..., хәтфә...; *бархатное платье* — бархат күлмәк, хәтфә күлмәк; 2. *перен.* нәфис, йомшак, ягымлы (тавыш турында).

**БАРХО'ТКА** *ж.*— к. бархатка.

**БАРЧО'НОК, БАРЧУ'К** *м.* — дворян баласы, алпавыт баласы.

**БА'РЩИНА** *ж. мн.* нет — барщина (крепостное право вакытында крестьяннарны алпавыт файдасына көчләп эшләтү).

**БА'РЩИННЫЙ** — барщина...-ы; *барщинный день* — барщина көне.

**БА'РЫ: тары-бары или тары-бары-растабары** — лыгырдау, юк-бар сөйләү, суган сату, ләчтит сату.

**БА'РЫНЬКА** *ж.*— к. барыня.

**БА'РЫНЯ** *ж.* — 1. *устар.* (*обращение*) бикә, байбикә; 2. *устар.* (*помещица*) хатын алпавыт; 3. *перен. неодобр.* барыня, бикә.

**БА'РЫНЯ II** *ж.* — барыня (рус халык биюе көе).

**БАРЫ'Ш** *м.*— табыш, файда.

**БАРЫ'ШНИК** *м.*— барышник, алып-сатар (1. атлар белән сату итүче; 2. театр билетларын үз бәясенә алып кыйммәтрәк бәягә сатучы).

**БАРЫ'ШНИЧАТЬ** *несов.*— барышниклык итү, алып-сатып йөрү.

**БАРЫ'ШНИЧЕСКИЙ** — барышник...-ы; *барышнические проценты* — барышник процентлары.

**БА'РЫШНЯ** *ж. устар.* — 1. (*девушка*) туташ; 2. барин кызы.

**БАРЬЕ'Р** *м.*— барьер, киртә, комачау. ◇ **Поставить на барьер** — дуэльгә чакыру, эшне дуэльгә илтеп җиткерү.

**БАРЬЕ'РНЫЙ** *спорт.* — барьерлык...; *барьерный материал* — барьерлык материал.

**БАС** *м.*— бас (1. ирләрнең иң калын тавышы; 2. шундый тавыш белән җырлаучы; 3. калын стройлы тынлы яки кыллы музыка коралы).

**БА'СЕНКА** *ж. разг.*— кечкенә мәсәл, мәсәлчек.

**БА'СЕННИК** *м.*— мәсәлләр җыентыгы.

**БА'СЕННЫЙ** — мәсәл...-ы; *басенный стиль* — мәсәл стиле.

**БАСИ'СТЫЙ** — калын тавышлы. ◇ **Басистый смех** — калын тавыш белән көлү. **Басистые звуки** — калын, яңгыравыклы авазлар.

**БАСИ'ТЬ** *несов.* — калын тавыш белән сөйләү (җырлау).

**БАСИ'ЩЕ** *м.*— артык калын бас.

**БАСКА'К** *м. истор.* — баскак (борынгы татар ханнарының салым җыйнаучы вәкилләре).

**БАСКЕТБО'Л** *м. спорт.*— баскетбол (туп ыргыту уены).

**БАСКЕТБОЛИ'СТ** *м.*, **БАСКЕТБОЛИ'СТКА** *ж. спорт.*— баскетболчы.

**БАСКЕТБО'ЛЬНЫЙ** *спорт.* — баскетбол...-ы; *баскетбольная команда* — баскетбол командасы.

**БА'СКИ** *м.*— басклар (Пиреней тауларының көнбатышында яшәүче халык).

**БАСМА'** *ж.*— басма (татар ханлыгы чорында хан тамгасы төшерелгән печать).

**БАСМА'Ч** *м.* — басмачы (Урта Азиядә гражданнар сугышы чорында буржуазия, феодаллар һәм муллалар тарафыннан оештырылган контрреволюцион хәрәкәттә катнашучы бандит).

**БАСМА'ЧЕСКИЙ** — басмачы...-ы, басмачылар...-ы; *басмаческий отряд* — басмачылар отряды.

**БАСМА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — 1. басмачылык; 2. *собир.* басмачылар.

**БАСНОПИ'СЕЦ** *м.* — мәсәлче, мәсәл язучы.

**БАСНОСЛО'ВИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *устар.* к. мифология; 2. *собир.* уйдырмалар, кеше ышанмаслык хикәяләр.

**БАСНОСЛО'ВНО** *нареч.* — ышанмаслык, чиктән тыш.

**БАСНОСЛО'ВНОСТЬ** *ж.*— уйдырма.

**БАСНОСЛО'ВНЫЙ** — 1. мифологик; 2. кеше ышанмаслык, акылга сыймаслык; чиктән тыш; чиктән тыш зур; *баснословная дешевизна* — чиктән тыш арзанчылык; *баснословная прибыль* — чиктән тыш зур табыш.

**БАСНЬ** *ж.*— к. басня 1.

**БА'СНЯ** *ж.*— 1. мәсәл; 2. *перен.* уйдырма, ялган, ышанмаслык ялган хәбәр (сүз).

**БАСОВИ'ТЫЙ** — к. басистый.

**БАСО'К** *м.*— 1. калын тавышлы кыл (музыка коралында); 2. уртача калын тавыш.

**БАСО'Н** *м.*— кәйтән, ука.

**БАСО'ННЫЙ** — кәйтән...-ы; ука...-ы; *басонное производство* — кәйтән производствосы.

**БАСО'НЩИК** *м.*, **БАСО'НЩИЦА** *ж.* — кәйтән остасы, ука остасы.

**БАССЕ'ЙН** *м.* — бассейн (1. су җыелыр өчен ясалган зур урын — сулык, сусаклагыч, ясалма күл; 2. диңгезне, күлне яки елганы һәм аларга коя торган барлык елгаларны эченә алган территория; 3. казылма байлыклар ята торган өлкә).

**БА'СТА** *межд.* — җитәр! җитте! булды! бетте!

**БАСТИ'ЛИЯ** *ж.* — Бастилия (1. Парижда дәүләт төрмәсе; 1789 елда баш күтәрүче халык тарафыннан алынган һәм җимерелгән; 2. *перен.* зур политик төрмәләрнең гомуми кушаматы).

**БАСТИО'Н** *м. устар. воен.* — бастион (бишпочмак формасында төзелгән крепость, хәрби ныгытма).

**БАСТИО'ННЫЙ** *устар. воен.* — бастион...-ы; *бастионные орудия* — бастион туплары.

**БАСТОВА'НИЕ** *ср. спец.* — бастование (әйләнеп тора торган щеткалы щётка белән тукымаларны эшкәртү процессы).

**БАСТОВА'ТЬ** *несов.* — эш ташлау, забастовка ясау.

**БАСТР** *м.* — бастр (түбән сортлы сары шикәр комы).

**БАСТУ'ЮЩИЙ** — эш ташлаучы, забастовкачы.

**БАСУРМА'Н** *м. устар.* — мөселман, басурман (электә христианнар тарафыннан мөселманнарга, шулай ук гомумән христиан булмаганнарга бирелгән исем).

**БАСУРМА'НИН** *м.*, **БАСУРМА'НКА** *ж. устар.* — к. басурман.

**БАСУРМА'НСКИЙ** *устар.* — мөселман...-ы, басурман...-ы; *басурманская вера* — басурман дине.

**БАСУРМА'НСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.* — мөселманлык, басурманлык.

**БАСЫ'** — гармонь бакалары (гармоньның сул кул ягындагы калын тавыш чыгара торган телләре).

**БАТАЛИ'СТ** *м. искус.* — баталист (сугыш күренешләре төшерүче художник).

**БАТА'ЛИЯ** *ж.* — 1. *устар.* сугыш, орыш; 2. *перен. разг. шутл.* ызгыш, талаш, кычкырыш.

**БАТА'ЛЬНЫЙ** *искус.* — баталь..., хәрби күренешләрне сурәтли торган.

**БАТАЛЬО'Н** *м. воен.* — батальон, баталион.

**БАТАЛЬО'ННЫЙ** *воен.* — 1. батальон...-ы; *батальонный фельдшер* — батальон фельдшеры; 2. *в знач. сущ.* батальон командиры.

**БАТА'Н** *м.* — кылыч (туку станогында).

**БАТАРЕ'ЕЦ** *м.* — батарея солдаты.

**БАТАРЕ'ЙКА** *ж.* — кечкенә батарея.

**БАТАРЕ'ЙНЫЙ** *воен.* — батарея...-ы; *батарейный огонь* — батарея уты.

**БАТАРЕ'Я** *ж.* — батарея (1. *воен.* артиллериядә берничә орудиедән тора торган гаскәри берәмлек һәм аның урнашкан позициясе; 2. *эл.* үзара берләштерелгән берничә электротехник элемент яки аккумулятор).

**БАТА'Т** *м. бот.* — батат, татлы бәрәңге (җылы якларда үстерелә торган үсемлек; бүлбеләре ашауга китә).

**БА'ТЕНЬКА** *м. простореч.* — 1. әткәй; 2. *(фам. обращение)* туганкай (ят кешегә карата).

**БАТИМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет — батиметрия (су тирәнлекләрен үлчәү).

**БАТИ'СТ** *м. текст.* — батист (тукыма).

**БАТИ'СТОВЫЙ** — 1. батист(тан тегелгән); *батистовое платье* — батист күлмәк; 2. батист...-ы; *батистовое производство* — батист производствосы.

**БАТИСФЕ'РА** *ж.* — батисфера (1. диңгез тирәнлеге; 2. диңгез тирәнлекләрен өйрәнү коралы).

**БАТМА'Н** *м.* — батман (электә авырлык үлчәве).

**БАТО'Г** *м.*, **БАТОЖО'К** *м. устар.* — 1. таяк; 2. таяк, юан чыбык (җәзалау, суктыру өчен).

**БАТО'МЕТР** *м.* — батометр (диңгезнең, күлнең төрле тирәнлекләреннән су алу приборы).

**БАТО'Н** *м.* — батон (1. озынча булка; 2. озынча баллы прәннек).

**БАТРА'К** *м.* — батрак, ялчы (алпавыт яки кулак хуҗалыгында).

**БАТРА'ЦКИЙ, БАТРА'ЧЕСКИЙ** — батраклар...-ы; *батрацкие депутаты* — батраклар депутатлары.

**БАТРА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — 1. батраклык; 2. *собир.* батраклар.

**БАТРА'ЧИЙ** — батрак...-ы; *батрачий труд* — батрак хезмәте.

**БАТРА'ЧИТЬ** *несов.* — батраклык итү, ялчы булып эшләү (алпавыт, кулак хуҗалыгында).

**БАТРА'ЧКА** *ж.* — к. батрак.

**БА'ТЬКА** *м. обл. фам. вульг.* — әткәй.

**БА'ТЬКО** *м.* — батько (1. гражданнар сугышы чорында контрреволюцион банда башлыгы; 2. *истор.* Украинада атаман яки аерым эш итә торган гаскәри часть башлыгы).

**БА'ТЮШКА** *м. устар.* — 1. *(отец)* әткәй; 2. *разг. (обращение)* атакай, туганкай, агай; 3. *(обращение к духовному лицу)* хәзрәт, тәкъсир; 4. *разг. (священник)* поп. ◇ **Батюшки (мои)** *разг.* — абау! Атакай! Бу ни бу!

**БА'ТЮШКИН** — 1. этинең, әтинеке; 2. попның, попныкы.

**БА'ТЯ** *м. простореч.* — к. батюшка 1.

**БАУ'Л** *м.* — баул, юл сандыгы.

**БАУ'ЛЬЧИК** *м.* — кечкенә баул.

**БАХ!** *межд.* — шалт! шап! доңк! шарт! гөрс!

**БА'ХАТЬ** *несов.* — к. бахнуть.

**БАХВА'Л** *м. разг.* — мактанчык, шапырынчы.

**БАХВА'ЛИТЬСЯ** *несов. простореч.* — мактану, шапырыну.

**БАХВА'ЛКА** *ж. простореч.* — мактанчык, шапырынучан (хатын-кыз).

**БАХВА'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — мактанчыклык, шапырынучанлык.

**БА'ХНУТЬ** *сов.*— 1. гөрселдәп кую, шарт итү, донк итү; кинәт каты тавыш ишетелеп китү; 2. кундыру, тондыру, шап итеп сугу; 3. шалтыратып төшереп вату.

**БА'ХНУТЬСЯ** *сов.* — 1. бәрелү; 2. гөрселдәп егылу.

**БАХРОМА'** *ж. мн.* нет — чук, чачак.

**БАХРО'МЧАТЫЙ** — 1. чуклы, чачаклы; 2. чачакка охшаган.

**БАХТАРМА'** *ж.* — бахтарма (хайван тиресенең эчке ягы).

**БА'ХУС** *м. устар.* — 1. аракы; 2. Бахус (*миф.* аракы һәм кәеф-сафа алласы).

**БАХЧА'** *ж.*— бакча (кавын-карбыз бакчасы).

**БАХЧЕ'ВНИК** *м.* — бакчачы (1. кавын-карбыз бакчасы хуҗасы; 2. бакча каравылчысы).

**БАХЧЕВО'Д** *м.*— бакчачы (кавын-карбыз бакчачылыгы белән шөгыльләнүче).

**БАХЧЕВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — бакчачылык (кавын-карбыз бакчачылыгы).

**БАХЧЕВО'Й** — бакча...-ы; *бахчевые культуры* — бакча культуралары.

**БАЦ!** *межд.*— чалт! шалт! донк!

**БА'ЦНУТЬ** *сов. просторeч.*— к. бахнуть.

**БАЦИ'ЛЛА** *ж.*— бацилла (авыру тудыра торган микробларның бер төре).

**БАЧО'К** *м.*— кечкенә бак.

**БАШ: баш на баш** — башма-баш.

**БА'ШЕНКА** *ж.*— кечкенә башня, манара, каланча.

**БА'ШЕННЫЙ** — башня...-ы; *башенные часы* — башня сәгате.

**БАШИБУЗУ'К** *м.*— 1. *истор.* башыбозык (Төркиядә регуляр булмаган гаскәр солдаты); 2. *перен.* башкисәр, юлбасар.

**БАШКА'** *ж. мн.* нет, *разг. фам.*— 1. баш; 2. *перен.* зиһенле кеше, башлы кеше. ◇ **У него тупая башка** — ул аңгыра кеше.

**БАШКИ'Р,** *устар.* **БАШКИ'РЕЦ** *м.* — башкорт.

**БАШКИ'РКА** *ж.*— башкорт хатын-кызы.

**БАШКИ'РСКИЙ** — башкорт...-ы; *башкирский язык* — башкорт теле.

**БАШКИ'РЫ** *мн.*, **БАШКИ'РЦЫ** *мн. устар.*— башкортлар, башкорт халкы.

**БАШКОВА'ТЫЙ, БАШКОВИ'ТЫЙ** *простореч.*— акыллы, зиһенле, башлы.

**БАШЛЫ'К** *м.*— башлык (баш киеме).

**БАШМА'К** *м.* — 1. башмак (аяк киеме); 2. *тех.* башмак, терәк, калып (ватылудан саклау өчен хезмәт итә торган төрле җайланмаларның атамасы). ◇ **У жены под башмаком** *разг.*— хатыны типкесендә; хатынының колы.

**БАШМА'ЧНИК** I *м.*, **БАШМА'ЧНИЦА** *ж.*— башмакчы, башмак тегүче.

**БАШМА'ЧНИК** II *м.*— башмачник (вагон көпчәкләре астына тормоз терәкләре куючы эшче).

**БАШМА'ЧНИЧАТЬ** *несов.* — башмакчылык белән (башмак тегү белән) шөгыльләнү.

**БАШМА'ЧНЫЙ** — башмак...-ы; *башмачная колодка* — башмак калыбы.

**БАШМАЧО'К** *м.* — 1. кечкенә башмак; 2. декоратив үсемлек.

**БА'ШНЯ** *ж.*— башня, манара, каланча.

**БАШТА'Н** *м.*— к. бахча.

**БА'Ю-БА'ЮШКИ-БАЮ'** *межд.* — әлли-бәлли, бәү-бәү, бәлли-бәү, әллүки-бәллүки.

**БАЮ'КАНЬЕ** *ср. мн.* нет — к. баюкать.

**БАЮ'КАТЬ** *несов.*— бәү-бәү иттерү (баланы); көйли-көйли тирбәтү, йоклату, юату.

**БАЯДЕ'РА, БАЯДЕ'РКА** *ж.* — баядерка (Һиндстан биюче һәм җырчы хатын-кызларына европалылар тарафыннан бирелгән исем).

**БАЯ'Н** *м.*— баян (музыка коралы).

**БАЯНИ'СТ** *м.*— баянчы, баянист, баянда уйнаучы.

**БА'ЯТЬ** *несов. обл.*— сөйләү, әйтү.

**БДЕТЬ** *несов. устар.*— 1. уяу булу, йокламау, вакытны йокламыйча үткәрү; 2. нык кайгырту, күзәтү.

**БДИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — сизгерлек, уяулык, саклык.

**БДИ'ТЕЛЬНЫЙ** — сизгер, уяу, сак.

**БЕБЕ'** *ср. нескл. разг.*— бәбәй, бәби.

**БЕГ** *м.*— 1. *только ед. (действие)* йөгерү; 2. *спорт.* йөгереш, узыш. ◇ **Бег времени** — вакыт үтүе.

**БЕГА'** *мн.*— 1. бәйге, чабыш, ат чабышы, ат узыштыру; 2. бәйге урыны (атлар узыштыру урыны, ипподром); 3. *устар.* качкынлык; *находиться в бегах* — качкынлыкта булу.

**БЕ'ГАНЬЕ** *ср.*— 1. к. бегать; 2. к. беготня.

**БЕ'ГАТЬ** *несов.* — 1. *(вообще)* йөгерү; *(в разных направлениях)* йөгереп йөрү; 2. качып йөрү; *от дела не бегай* — эштән качып йөрмә; 3. *перен.* ялт-йолт итеп тору, уйнаклап тору; *глаза его так и бегают* — аның күзләре ялт-йолт итеп тора.

**БЕГЕМО'Т** *м.*— бегемот (су айгыры).

**БЕГЛЕ'Ц** *м.*— качкын.

**БЕ'ГЛО** *нареч.*— 1. *(поверхностно)* тиз-тиз, өстән-өстән генә, ашыгып; 2. *(легко, без затруднений)* йөгерек, тиз (уку); 3. *(быстро, мимолётно)* тиз генә, җәһәт кенә.

**БЕ'ГЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — йөгереклек, тизлек, җәһәтлек (укуда, музыка коралында уйнауда).

**БЕ'ГЛЫЙ** I — качкын.

**БЕ'ГЛЫЙ** II — 1. *(поверхностный)* өстән-өстән генә, игътибарсыз гына (эшләнгән); 2. *(достаточно свободный)* йөгерек, тиз (мәсәлән, уку).

**БЕГЛЯ'НКА** *ж.*— к. беглец.

**БЕГОВО'Й** — 1. чабыш...-ы; *беговая лошадь* — чабыш аты; 2. узыш...-ы, узышу...-ы; *беговые лыжи* — узыш чаңгысы.

**БЕГО'М** *нареч.* — йөгереп, тиз генә. ◇ **Бежать бегом** — бик тиз йөгерү.

**БЕГО'НИЯ** *ж. бот.*— бегония (гөл).

**БЕГОТНЯ'** *ж. мн.* нет — арлы-бирле йөгереп йөрү; ыгы-зыгы; *весь день прошёл в беготне* — арлы-бирле йөгереп көнем үтте.

**БЕ'ГСТВО** *ср. мн.* нет — 1. качу, качып китү; 2. *(беспорядочное отступление)* тәртипсез чигенү (сугышта).

**БЕГУ'Н** *м.* — 1. *(о человеке)* йөгерек, (яхшы) йөгерүче; 2. *(о коне)* чапкын, йөге-

рек, чабыш (ат); 3. *тех.* бегун (металлдан яки таштан ясалган авыр тегермән ташы).

**БЕГУНКИ'** *мн.* (*ед.* бегунок *м.*)—1. *спорт.* чабыш арбасы, чабыш чанасы; 2. *(у паровоза)* кечкенә көпчәкләр; 3. *зоол.* йөгерек кошлар (комлы далаларда, чүлләрдә яшиләр).

**БЕГУ'НЬЯ** *ж.*— к. бегун 1.

**БЕДА'** *ж.* — 1. бәла, бәла-каза, хәвеф-хәтәр, кайгы, бәхетсезлек; 2. *в знач. сказ.* аптыраш; *просто беда!*— аптыраш! ◇ **Беда как...** *разг.* — бик; *беда как есть хочу* — бик ашыйсы килә. **Что за беда!** *разг.* — борчылыр урын юк! булса соң! булса ни кайгы! **Не беда** — зарар юк, куркырлык урын юк. **На беду** *разг.* — бәхетсезлеккә каршы, бәлагә каршы.

**БЕДЛА'М** *м.* — тәртипсезлек, ыгы-зыгы, шау-шу, чуалчыклык.

**БЕ'ДНЕНЬКИЙ** — бичаракай, мескенкәй.

**БЕДНЕ'ТЬ** *несов.* — ярлылану, фәкыйрьләнү.

**БЕ'ДНО** *нареч.*— ярлы, фәкыйрь.

**БЕ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ярлылык, фәкыйрьлек; мохтаҗлык.

**БЕДНОТА'** *ж. мн.* нет — 1. мохтаҗлык, ярлылык; 2. *собир.* ярлы-ябагай, ярлылар, ярлы халык, юксыллар.

**БЕ'ДНЫЙ** — 1. ярлы, фәкыйрь, мохтаҗ; 2. гарип, кызганыч; *лишь кое-где торчали бедные ветлы* — ара-тирә гарип өянкеләр генә тырпаеп торалар иде; 3. мескен, бичара.

**БЕДНЯ'ГА** *м.*— мескен, бичара.

**БЕДНЯ'ЖКА, БЕДНЯ'ЖЕЧКА** *м.* и *ж.*— 1. мескенкәй, бичаракай; 2. *ж.* мескен, бичара (хатын-кыз).

**БЕДНЯ'К** *м.*— ярлы, фәкыйрь, юксыл.

**БЕДНЯ'ЦКИЙ** — ярлылар...-ы; *бедняцкие массы* — ярлылар массасы.

**БЕДНЯ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — ярлы крестьяннар.

**БЕДНЯ'ЧКА** *ж.* — к. бедняк.

**БЕДО'ВЫЙ** *разг.* — кыю, чая, шук; булдыклы, үткен, тапкыр.

**БЕДОКУ'Р** *м. разг. фам.* — шаян, тиктормас, шук; азгын, тыйнаксыз.

**БЕДОКУ'РИТЬ** *несов.* — шаярып борчу, тынгысызлау; тынычсызлау; азгынлык эшләү, бәла китерү, зыян эшләү.

**БЕ'ДРЕННЫЙ** — бот... -ы; *бедренная кость* — бот сөяге.

**БЕДРО'** *ср.* — бот.

**БЕ'ДСТВЕННЫЙ** — бәлале, бәла-казалы, хәвефле, авыр.

**БЕ'ДСТВИЕ** *ср.* — бәла-каза, һәлакәт, афәт, зур бәхетсезлек.

**БЕ'ДСТВОВАТЬ** *несов.* — мохтаҗлыкта яшәү, фәкыйрьлектә яшәү, авыр көн күрү.

**БЕДУИ'Н** *м.* — бәдәви, күчмә гарәп.

**БЕДУИ'НКА** *ж.* — бәдәви хатын-кыз.

**БЕДУИ'НСКИЙ** — бәдәви...-ы; бәдәвиләр...-ы; *бедуинский обычай* — бәдәвиләр гадәте.

**БЕЖ** *неизм. прил.* — аксыл-көрән (төс).

**БЕЖА'ТЬ** *несов.* — 1. *(вообще)* йөгерү; 2. *(туда)* йөгереп бару, *(сюда)* йөгереп килү; 3. *(быстро передвигаться)* чабу; кызу бару; 4. *(торопливо итти)* чабу, ашыгу; 5. качу, качып китү; *бежать из плена* — пленнан качу; 6. ташу; *самовар бежит* — самовар ташый. ◇ **Годы бегут** — еллар үтә. **Вода бежит из крана** — краннан су ага. **Облака бегут** — болытлар агыла. **Тропинка бежит в гору** — сукмак тауга менеп китә. **Слёзы бегут** — күз яше ага. **Часы бегут** — сәгать алга китә.

**БЕ'ЖЕВЫЙ** *разг.* — к. беж.

**БЕ'ЖЕНЕЦ** *м.*, **БЕ'ЖЕНКА** *ж.* — качак (сугыш яки башка берәр сәбәп аркасында торган җиреннән качкан кеше).

**БЕ'ЖЕНСКИЙ** — качаклар...-ы; *беженский приют* — качаклар приюты.

**БЕ'ЖЕНСТВО** *ср. мн.* нет — качаклык (туган-үскән җирләрне калдырып китү, мәсәлән, сугыш сәбәпле).

**БЕЗ** *предлог* — 1. ... -сыз; *без воды жизнь невозможна* — сусыз яшәү мөмкин түгел; 2. ...-дан башка; *без посторонней помощи* — чит кешеләрнең ярдәменнән башка; 3. югында, юк чакта; *без тебя приходил брат* — син югында (юк чакта) абыең (энең) килгән иде; 4. ким; *без двадцати граммов кило* — килодан егерме грамм ким. ◇ **Без пяти шесть** — алты туларга биш минут. **Без малого** — аз дигәндә. **Без оглядки** — артына карамыйча.

**БЕЗАВАРИ'ЙНЫЙ** — авариясез.

**БЕЗАЛА'БЕРНО** *нареч.* — тәртипсез рәвештә, тәртипсез итеп, ничек туры килсә шулай, бутап.

**БЕЗАЛА'БЕРНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәртипсезлек, юньсезлек, рәтсезлек.

**БЕЗАЛА'БЕРНЫЙ** — тәртипсез, юньсез, рәтсез.

**БЕЗАЛА'БЕРЩИНА** *ж. мн.* нет — буталчыклык, чуалчыклык, ерып чыккысыз тәртипсезлек.

**БЕЗАЛКОГО'ЛЬНЫЙ** — алкогольсез.

**БЕЗАПЕЛЛЯЦИО'ННО** *нареч.* — катгый рәвештә; апелляциясез, каршы килә алмаслык итеп, сүз әйтмәслек итеп, шик калдырмаслык итеп.

**БЕЗАПЕЛЛЯЦИО'ННЫЙ** — 1. апелляциясез; 2. катгый, каршы килә алмаслык.

**БЕЗБЕ'ДНО** *нареч.*—мохтаҗлыксыз, җиткелекле.

**БЕЗБЕ'ДНЫЙ** — мохтаҗлыксыз (мәсәлән, тормыш).

**БЕЗБЕЛКО'ВЫЙ** — аксымсыз, аксым катнашмаган.

**БЕЗБИЛЕ'ТНЫЙ** — билетсыз, билет алмаган, билеты юк.

**БЕЗБО'ЖИЕ** *ср. мн.* нет — алласызлык, алланы танымау.

**БЕЗБО'ЖНИК** *м.*, **БЕЗБО'ЖНИЦА** *ж.* — 1. алласыз, динсез, дәһри; 2. *устар. бран.* вөҗдансыз кеше, инсафсыз кеше, оятсыз кеше.

**БЕЗБО'ЖНО** *нареч.* — оятсыз рәвештә, инсафсыз рәвештә, күзгә карап.

**БЕЗБО'ЖНЫЙ** — 1. дингә каршы; *безбожное движение* — дингә каршы хәрәкәт; 2. *перен.* оятсыз, вөҗдансыз, намуссыз, ин-

сафсыз; *безбожный враль* — оятсыз ялганчы.

**БЕЗБОЛЕ'ЗНЕННО** *нареч.* — 1. авыртусыз, авырттырусыз, авырттырмыйча; 2. *перен.* зарарсыз, зыянсыз, зарар китермичә.

**БЕЗБОЛЕ'ЗНЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. авыртусызлык; 2. зарарсызлык.

**БЕЗБОЛЕ'ЗНЕННЫЙ** — 1. авыртусыз, авырттырусыз; 2. *перен.* зарарсыз.

**БЕЗБО'ЛЬНЫЙ** — *к.* безболезненный 1.

**БЕЗБОРО'ДЫЙ** — 1. сакалсыз, күсә; 2. *(слишком юный)* яшь.

**БЕЗБОЯ'ЗНЕННО** *нареч.* — курыкмыйча; кыю рәвештә.

**БЕЗБОЯ'ЗНЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — куркусызлык, кыюлык.

**БЕЗБОЯ'ЗНЕННЫЙ** — куркусыз, кыю.

**БЕЗБРА'ЧИЕ** *ср. мн.* нет — өйләнмәү, кияүгә чыкмау.

**БЕЗБРА'ЧНЫЙ** — өйләнмәгән, кияүгә чыкмаган.

**БЕЗБРЕ'ЖИЕ** *ср.* — к. безбрежность.

**БЕЗБРЕ'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — очсыз-кырыйсызлык.

**БЕЗБРЕ'ЖНЫЙ** — 1. ярсыз, читсез; 2. очсыз-кырыйсыз, бик зур, иксез-чиксез.

**БЕЗБРО'ВЫЙ** — кашсыз, сирәк кашлы.

**БЕЗБУ'РНЫЙ** — тын, тыныч, хәвеф-хәтәрсез, шау-шусыз.

**БЕЗ ВЕ'ДОМА** — рөхсәтсез-нисез, алдан белдермичә.

**БЕЗВЕ'ДРЕННЫЙ**—явым-чәчемле, явымтөшемле, бозык (һава).

**БЕЗВЕ'ДРИЕ** *ср.* — бозык һава, көн бозыклык, явым-чәчем, явымлы көннәр.

**БЕЗВЕ'РИЕ, БЕЗВЕ'РЬЕ** *ср. мн.* нет — ышанмау, инанмау, динсезлек.

**БЕ'З ВЕСТИ** — хәбәрсез.

**БЕЗВЕ'СТНО** *нареч.* —билгесез генә, дансыз гына, беленмичә, танылмыйча.

**БЕЗВЕ'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — хәбәрсезлек, билгесезлек.

**БЕЗВЕ'СТНЫЙ** — билгесез, хәбәрсез; гади генә, данлыксыз; *в семье безвестной я родился* — гади генә бер семьяда тудым мин.

**БЕЗВЕ'ТРЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. безветрие.

**БЕЗВЕ'ТРЕННЫЙ** — җилсез, дымык, тын, ышык.

**БЕЗВЕ'ТРИЕ** *ср. мн.* нет — җилсезлек, тынлык.

**БЕЗВЗЯ'ТОЧНОЕ ВРЕ'МЯ** — табышсыз вакыт (умартачылыкта).

**БЕЗВИ'ННО** *нареч.* — гаепсезгә, юкка гына, нахакка, хаксызга.

**БЕЗВИ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — гаепсезлек, гөнаһсызлык.

**БЕЗВИ'ННЫЙ** — гаепсез, гөнаһсыз, саф күңелле.

**БЕЗВКУ'СИЕ** *ср. мн.* нет — 1. татымсызлык, тәмсезлек, авызда тәм булмау; начар, әшәке тәм; 2. к. безвкусица 2.

**БЕЗВКУ'СИЦА** *ж. мн.* нет — 1. тәмсезлек; тәмсез (әйбер); 2. зәвыксызлык, татымсызлык; тәм белмәү, матурлыкны аера белмәү, матурлыктан тәм таба белмәү, матурлыкны аңламау.

**БЕЗВКУ'СНО** *нареч.* — тәмсез итеп; зәвыксызлык белән, татымсыз итеп; вкуссыз.

**БЕЗВКУ'СНЫЙ** — 1. тәмсез, төче; *всякая еда больному казалась безвкусной* — авыруга һәртөрле аш тәмсез булып күренә иде; 2. *неодобрит. (лишённый изящества)* шыксыз, килешсез, ягымсыз, ятышсыз; 3. зәвыксыз, татымсыз, вкуссыз; *безвкусный человек* — вкуссыз кеше.

**БЕЗВЛА'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — дымсызлык.

**БЕЗВЛА'ЖНЫЙ** — дымсыз.

**БЕЗВЛА'СТИЕ** *ср. мн.* нет — властьсызлык; анархия.

**БЕЗВЛА'СТНО** *нареч.*— көчсез генә, буйсынучан рәвештә.

**БЕЗВЛА'СТНЫЙ** — 1. көчсез, властьсыз; 2. *устар.* идарә итүчесе булмаган.

**БЕЗВО'ДНЫЙ** — сусыз, суы аз.

**БЕЗВО'ДЬЕ** *ср. мн.* нет — сусызлык, суы азлык.

**БЕЗВОЗБРА'ННО** — тоткарламыйча, тыелмыйча, иркен генә.

**БЕЗВОЗБРА'ННЫЙ** — тоткарлыксыз, тарсынусыз, иркен.

**БЕЗВОЗВРА'ТНО** — кайтарусыз; кайтусыз, кайтмаска, мәңгегә.

**БЕЗВОЗВРА'ТНОЕ** *в знач. сущ.* — кайтмас нәрсә, кайтмый торган (нәрсә).

**БЕЗВОЗВРА'ТНЫЙ** — кайтарусыз, кайтарылмас; кайтару мөмкин булмаган.

**БЕЗВОЗДУ'ШНЫЙ** — һавасыз; *безвоздушное пространство* — һавасыз бушлык.

**БЕЗВОЗМЕ'ЗДНО** *нареч.* — бушлай гына; түләүсез, түләүсез рәвештә.

**БЕЗВОЗМЕЗ'ДНЫЙ** — түләүсез, бушлай, буш, тиген.

**БЕЗВО'ЛИЕ** *ср. мн.* нет — ихтыярсызлык, җебегәнлек, йомшаклык.

**БЕЗВОЛО'СЫЙ** — чәчсез.

**БЕЗВО'ЛЬНО** *нареч.* — ихтыярсыз, ирексездән, үзе дә сизмичә, үзен-үзе тота алмыйча.

**БЕЗВО'ЛЬНЫЙ** — ихтыярсыз, йомшак характерлы, җебегән.

**БЕЗВРЕ'ДНО** *нареч.* — зарарсыз-зыянсыз гына, сау-сәламәт кенә, хәвеф-хәтәрсез генә.

**БЕЗВРЕ'ДНЫЙ** — зарарсыз, зыянсыз.

**БЕЗВРЕ'МЕННИК** *м. бот.* — эт үләне (агулы үлән).

**БЕЗВРЕ'МЕННО** *нареч.* — вакытсыз, вакытыннан элек.

**БЕЗВРЕ'МЕННЫЙ** — вакытсыз, иртә, вакытыннан элек.

**БЕЗВРЕ'МЕНЬЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. *(пора невзгод)* авыр вакыт, бәхетсезлекләр, бәла-казалар вакыты; 2. *(эпоха застоя)* җәмгыятьтә торгынлык, реакция чоры; 3. *(ненастье)* һаваның бозылуы.

**БЕЗВЫ'ГОДНО** *нареч.* — файдасызга, файда күрмичә.

**БЕЗВЫ'ГОДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — файдасызлык.

**БЕЗВЫ'ГОДНЫЙ** — файдасыз.

**БЕЗВЫ'ЕЗДНО** *нареч.* — читкә чыкмыйча, беркая да китмичә, китмәстән.

**БЕЗВЫ'ЕЗДНЫЙ** — даими, беркая да чыкмыйча, китмичә.

**БЕЗВЫ'ХОДНО** *нареч.* — өйдән чыкмыйча, беркая да чыкмыйча.

**БЕЗВЫ'ХОДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — котылгысызлык, чарасызлык.

**БЕЗВЫ'ХОДНЫЙ** — 1. котылгысыз, чарасыз, аптыраш; *безвыходное положение* — аптыраш хәл; 2. беркая да чыкмыйча...; *безвыходное сиденье дома* — беркая да чыкмыйча өйдә утыру.

**БЕЗГЛА'ВЫЙ** — башы киселгән, башсыз.

**БЕЗГЛА'ЗЫЙ** — күзсез; сукыр.

**БЕЗГЛА'СНО** *нареч.* — 1. эндәшмичә, тын гына; 2. *устар.* яшертен.

**БЕЗГЛА'СНЫЙ** — 1. *книж. (безмолвный)* тын, тыныч; 2. *(несмелый)* кыюсыз, юаш; тавышы-тыны чыкмый торган; 3. *грам.* тавышсыз, укылмый торган (мәсәлән, ъ, ь хәрефләре).

**БЕЗГНЕ'ВНЫЙ** — ачусыз, юаш, йомшак күңелле.

**БЕЗГОЛО'ВЫЙ** — 1. *(лишённый головы)* башсыз, башы киселгән; 2. *перен. (глупый)* аңгыра, миңгерәү, томана, хәтерсез, мисез, башсыз, тавык мие эчкән.

**БЕЗГОЛО'СИЦА** *ж.* — тавыш бетү, тавыштан язу, тавыштан калу, тавышсызлык.

**БЕЗГОЛО'СНЫЙ** *лингв.* — тавышсыз (аваз).

**БЕЗГОЛО'СЫЙ** — тавышыннан язган; начар тавышлы, зәгыйфь тавышлы.

**БЕЗГРА'МОТНО** *нареч.* — надан.

**БЕЗГРА'МОТНОСТЬ** *ж. мн.* нет—1. укыйяза белмәүчелек; 2. наданлык.

**БЕЗГРА'МОТНЫЙ** — 1. *(не обученный грамоте)* укый-яза белмәүче; 2. *(невежественный)* надан.

**БЕЗГРАНИ'ЧНО** *нареч.* — 1. чиксез, очсыз-кырыйсыз; 2. бик нык, җан-тән белән; *безгранично любить* — бик нык ярату.

**БЕЗГРАНИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — чиксезлек, иксез-чиксезлек, чиге юклык.

**БЕЗГРАНИ'ЧНЫЙ** — 1. чиксез, иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз; *в знач. сказ.* чиге юк; 2. *перен.* чиксез, чиктән тыш (мәсәлән, шатлык, кайгы).

**БЕЗГРА'ННЫЙ** — очсыз-кырыйсыз, иксез-чиксез.

**БЕЗГРЕ'ШНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гөнаһсызлык, гаепсезлек.

**БЕЗГРЕ'ШНЫЙ** — гөнаһсыз, гаепсез, саф күңелле. ◇ Безгрешные доходы *ирон.* — взятка.

**БЕЗГРИ'ВЫЙ** — ялсыз.

**БЕЗДА'ННЫЙ** *устар.* — ясаксыз, пошлинасыз. ◇ Бeзданно-беспошлинно — ясаксыз-нисез, салымсыз-нисез, түләүсез генә.

**БЕЗДА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. талантсыз, булдыксыз (кеше), аңгыра; 2. булдыксызлык, уңмаганлык, сәләтсезлек, талантсызлык.

**БЕЗДА'РНЫЙ** — 1. сәләтсез, талантсыз; *бездарный поэт* — талантсыз шагыйрь; 2. талантсыз, сәләтсез эшләнгән; *бездарная картина* — талантсыз эшләнгән картина; 3. булдыксыз, уңмаган, эшлексез (кулыннан эш килми торган); *бездарный человек* — булдыксыз кеше.

**БЕЗДА'РЬ** *ж. мн.* нет—1. *собир.* булдыксызлар, уңмаганнар, уңмаган кешеләр; 2. талантсыз, сәләтсез (кеше).

**БЕЗДЕ'ЙСТВЕННО** *нареч.* — эшлеклелек күрсәтмичә; хәрәкәтсез рәвештә, чарасын күрмичә.

**БЕЗДЕ'ЙСТВЕННЫЙ** — хәрәкәтсез, тик торучы, эшсез; эшлеклелек күрсәтми торган.

**БЕЗДЕ'ЙСТВИЕ** *ср. мн.* нет — 1. хәрәкәтсезлек, эшлексезлек, тик яту; 2. *юрид.* чара кулланмау, гамьсезлек, булдыксызлык.

**БЕЗДЕ'ЙСТВОВАТЬ** *несов.* — 1. *(о человеке)* эшлексезлек күрсәтү, чара күрмәү; 2. эшләмәү, туктап тору, тик яту; *машина бездействует* — машина тик ята, эшләми.

**БЕЗДЕ'ЛИЦА** *ж.* — 1. вак-төяк, юк-бар нәрсә, әһәмиятсез нәрсә; 2. к. безделушка.

**БЕЗДЕ'ЛКА** *ж.* — к. безделица.

**БЕЗДЕЛУ'ШКА** *ж.* — вак-төяк бизәү әйберләре.

**БЕЗДЕ'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет — эшсезлек, тик йөрү; түшәмгә төкереп яту.

**БЕЗДЕ'ЛЬНИК** *м.*, **БЕЗДЕ'ЛЬНИЦА** *ж.* — 1. *(лентяй)* эшлексез, ялкау; 2. *бран. (негодник)* әшәке, кабахәт.

**БЕЗДЕ'ЛЬНИЧАТЬ** *несов.* — эшсез йөрү, ялкаулыкка сабышу, ялкаулыкка бирелү, ялкаулану.

**БЕЗДЕ'ЛЬНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет—к. безделье.

**БЕЗДЕ'ЛЬНО** *нареч.* — бернәрсә дә эшләмичә, тик кенә, эшсез.

**БЕЗДЕ'ЛЬНЫЙ** — 1. *(праздный)* эшсез; 2. әһәмиятсез, вак.

**БЕЗДЕ'НЕЖНЫЙ** — 1. акчасыз; *безденежный расчёт* — акчасыз расчёт; 2. акчасыз, акчага мохтаж.

**БЕЗДЕ'НЕЖЬЕ** *ср. мн.* нет — акчасызлык, акчага кытлык, акча булмау.

**БЕЗДЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — баласызлык, бала булмау.

**БЕЗДЕ'ТНЫЙ** — баласыз, баласы юк, баласы булмаган.

**БЕЗДЕФИЦИ'ТНЫЙ** — дефицитсыз.

**БЕЗДЕ'ЯТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — сүлпәнлек (эштә), салкын карау, салкынлык (эшкә), эшлексезлек.

**БЕЗДЕ'ЯТЕЛЬНО** *нареч.* — эшлеклелек күрсәтмичә.

**БЕЗДЕ'ЯТЕЛЬНЫЙ** — ялкау, эшлексез, сүлпән (эштә).

**БЕ'ЗДНА** *ж.* — 1. упкын, тирән чокыр; төпсез бушлык; 2. диңгез чоңгылы, тоба; 3. *перен.* чиксез күп, иксез-чиксез, исәпсез-хисапсыз; *бездна народу* — чиксез күп халык.

**БЕЗДО'ЖДНЫЙ** — яңгырсыз.

**БЕЗДО'ЖДЬЕ** *ср. мн.* нет—яңгырсызлык, корылык, явым-төшемсез чак.

**БЕЗДОКАЗА'ТЕЛЬНО** *нареч.* — дәлилсезнисез, дәлил китермичә.

**БЕЗДОКАЗА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — дәлилсезлек, нигезсезлек.

**БЕЗДОКАЗА'ТЕЛЬНЫЙ** — дәлилсез, нигезсез, исбат ителмәгән.

**БЕЗДО'ЛЬНЫЙ** — бәхетсез.

**БЕЗДО'МНЫЙ** — йорт-җирсез; хуҗасыз, иясез; *бездомная собака* — иясез эт.

**БЕЗДО'ННЫЙ** — 1. төпсез; 2. бик тирән. ◇ Бездонная бочка — 1. аракы мичкәсе (күп эчә торган кеше турында); 2. төпсез мичкә (күп, ләкин әрәм расход сорый торган бирәр нәрсә турында).

**БЕЗДОРО'ЖЬЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(отсутствие дорог)* юлсызлык, яхшы юллар юклык; 2. *(распутица)* юл өзеклек, юл өзелеп торган вакыт.

**БЕЗДОХО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — доходсызлык, табышсызлык, файдасызлык.

**БЕЗДОХО'ДНЫЙ** — доходсыз, табышсыз, файдасыз.

**БЕЗДУ'МНО** *нареч.* — уйламыйча, уйлап тормастан, ваемсыз рәвештә.

**БЕЗДУ'МНЫЙ** — ваемсыз, кайгысыз.

**БЕЗДУ'МЬЕ** *ср.* — ваемсызлык, кайгысызлык.

**БЕЗДУ'ШИЕ** *ср. мн.* нет — рәхимсезлек, шәфкатьсезлек, каты күңеллелек, кансызлык.

**БЕЗДУ'ШНО** *нареч.* — 1. *(безжалостно)* рәхимсез рәвештә, аямыйча; 2. *(сухо)* салкын, рухсыз, күңел бирмичә.

**БЕЗДУ'ШНЫЙ** — 1. *(мёртвый)* җансыз, үлек; 2. *(безжалостный)* рәхимсез, шәфкатьсез, каты күңелле, кансыз.

**БЕЗДЫ'МНЫЙ** — төтенсез.

**БЕЗДЫХА'ННЫЙ** — 1. *(мёртвый)* җансыз, үле; 2. тын; *наступила бездыханная ночь* — тын төн килеп җитте.

**БЕЗЖА'ЛОСТНО** *нареч.* — аяусыз (рәвештә), рәхимсез (рәвештә).

**БЕЗЖА'ЛОСТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — аяусызлык, рәхимсезлек, шәфкатьсезлек, кансызлык.

**БЕЗЖА'ЛОСТНЫЙ** — аяусыз, рәхимсез, шәфкатьсез, кансыз, кызганусыз, каты күңелле.

**БЕЗЖИ'ЗНЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — рухсызлык, дәртсезлек.

**БЕЗЖИ'ЗНЕННЫЙ** — 1. *(мёртвый)* җансыз; 2. *перен.* рухсыз, дәртсез, темпераментсыз.

**БЕЗЗАБО'ТНО** *нареч.* — гамьсез, ваемсыз, көенмичә, кайгысыз, берни дә уйламыйча.

**БЕЗЗАБО'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гамьсезлек, ваемсызлык.

**БЕЗЗАБО'ТНЫЙ** — гамьсез, ваемсыз, кайгысыз, хәсрәтсез; мәшәкатьсез, тыныч; *беззаботное житьё* — мәшәкатьсез тормыш.

**БЕЗЗАВЕ'ТНО** *нареч.* — үзен аямыйча, чын күңелдән, бирелеп, омтылып.

**БЕЗЗАВЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — фидакарьлек, үзен аямау.

**БЕЗЗАВЕ'ТНЫЙ** — үзен аямыйча эшләнгән; җаны-тәне белән эшләнгән, чын күңелдән эшләнгән; фидакарь; *беззаветная храбрость* — фидакарь батырлык. ◇ Беззаветная преданность — чын күңелдән бирелгәнлек. Беззаветная любовь — чын мәхәббәт, чиксез тирән мәхәббәт.

**БЕЗЗАКА'ТНЫЙ** — 1. баемас, батмас, баемый торган (кояш); 2. *перен.* иксез-чиксез, бетмәс-төкәнмәс.

**БЕЗЗАКО'НИЕ** *ср.* — законсызлык, закон бозу.

**БЕЗЗАКО'ННИК** *м.*, **БЕЗЗАКО'ННИЦА** *ж. устар.* — 1. *(нарушитель закона)* законсыз эш итүче, закон бозучы; 2. *(безнравственный)* әхлаксыз кеше, инсафсыз кеше, бозык кеше.

**БЕЗЗАКО'ННО** *нареч.* — законсыз рәвештә, законны бозып.

**БЕЗЗАКО'ННОСТЬ** *ж.* — законсызлык, законга каршылык.

**БЕЗЗАКО'ННЫЙ** — законсыз, законга сыймаган, законга каршы.

**БЕЗЗАСТЕ'НЧИВО** *нареч.* — оялмыйча, тартынмыйча, оятсыз рәвештә, әрсезләнеп.

**БЕЗЗАСТЕ'НЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — оятсызлык, әрсезлек, сөмсезлек.

**БЕЗЗАСТЕ'НЧИВЫЙ** — оятсыз, әрсез, сөмсез.

**БЕЗЗАЩИ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — таянычсызлык, таянычы булмау, яклаучысызлык, гаҗизлек.

**БЕЗЗАЩИ'ТНЫЙ** — яклаучысыз, таянычсыз, көчсез; гаҗиз; *дикарь беззащитен перед стихией* — вәхши кеше табигать көчләре алдында көчсез.

**БЕЗЗВУ'ЧНО** *нареч.* — тавышсыз-тынсыз.

**БЕЗЗВУ'ЧНЫЙ** — тавышсыз, аһәңсез.

**БЕЗЗЕМЕ'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет — җирсезлек; җиргә мохтаҗлык.

**БЕЗЗЕМЕ'ЛЬНЫЙ** — җирсез, җиргә мохтаҗ.

**БЕЗЗЛО'БИЕ** *ср. мн.* нет — ачусызлык, йомшак күңеллелек, эчкерсезлек, юашлык.

**БЕЗЗЛО'БНО** *нареч.* — ачусыз, эчкерсезлек белән, йомшак кына.

**БЕЗЗЛО'БНЫЙ** — ачусыз, йомшак күңелле, эчкерсез, юаш.

**БЕЗЗУ'БЫЙ** — 1. тешсез, теше юк; 2. *перен.* көчсез, зәгыйфь, йомшак; *беззубая критика* — көчсез тәнкыйть.

**БЕЗИДЕ'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет — идеясезлек, принципсызлык.

**БЕЗИДЕ'ЙНЫЙ** — идеясез, төп фикерсез, принципсыз.

**БЕЗИНИЦИАТИ'ВНЫЙ** — инициативасыз, дәртсез (яңалыклар, яхшыртулар кертүгә сәләтсез).

**БЕЗЛЕ'СНЫЙ** — урмансыз, урманга ярлы.

**БЕЗЛЕ'СЬЕ** *ср. мн.* нет — урмансызлык, урманга ярлылык.

**БЕЗЛИ'СТВЕННЫЙ, БЕЗЛИ'СТНЫЙ, БЕЗЛИ'СТЫЙ** — яфраксыз, ялангач, шәрә (агач).

**БЕЗЛИ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, **БЕЗЛИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — үзенчәлексезлек, йомшак характерлылык, йомшаклык.

**БЕЗЛИ'ЧНЫЙ** — үзенчәлексез, йомшак характерлы. ◇ Безличное предложение — иясез җөмлә. Безличный глагол — затланышсыз фигыль.

**БЕЗЛУ'ННЫЙ** — айсыз.

**БЕЗЛЮ'ДНЫЙ** — кешесез; тын, аулак, халык аз яши торган, кеше йөрми торган.

**БЕЗЛЮ'ДЬЕ** *ср. мн.* нет — кешесезлек, кешеләр юклык.

**БЕЗМА'ЛА** *нареч. простореч.* — аз дигәндә.

**БЕЗМА'ТОК** *м.* — анасыз ил, анасыз күч (умарта кортларында).

**БЕЗМЕ'ЗДНЫЙ** — к. безвозмездный.

**БЕЗМЕ'Н** *м.* — бизмән (үлчәү).

**БЕЗМЕ'РНЫЙ** — чиксез, чамасыз, чиктән тыш зур, чамадан тыш зур.

**БЕЗМО'ЗГЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — аңгыралык, ахмаклык, миңгерәүлек.

**БЕЗМО'ЗГЛЫЙ** *разг. бран.* — мисез, аңгыра, ахмак, миңгерәү.

**БЕЗМО'ЛВИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(молчание)* эндәшмәү; 2. *(тишина)* тынлык, тынычлык.

**БЕЗМО'ЛВНО** *нареч.* — эндәшмичә, берсүзсез, тып-тын гына.

**БЕЗМО'ЛВНЫЙ** — 1. *(молчаливый)* сүзсез, тавыш-тынсыз; 2. *(тихий)* тып-тын, тыныч.

**БЕЗМО'ЛСТВОВАТЬ** *несов.* — эндәшмәү, бер сүз дә әйтмәү, ләм-мим әйтмәү.

**БЕЗМУ'ЖНЯЯ** — ирсез, ирдән калган, тол хатын.

**БЕЗМЯТЕ'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тынычлык, борчылусызлык.

**БЕЗМЯТЕ'ЖНЫЙ** — тыныч, борчылусыз, гаугасыз.

**БЕЗНАДЁЖНО** *нареч.* — өметсезлек белән; ышанмыйча; өметсез; *безнадёжно больной* — өметсез авыру.

**БЕЗНАДЕ'ЖНОСТЬ, БЕЗНАДЁЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — өметсезлек, ышанычсызлык, таянычсызлык, чарасызлык.

**БЕЗНАДЕ'ЖНЫЙ, БЕЗНАДЁЖНЫЙ** — ышанычсыз, өметсез, таянычсыз, чарасыз.

**БЕЗНАДЗО'РНЫЙ** — караучысыз, күзәтүчесез; иясез.

**БЕЗНАКА'ЗАННО** *нареч.* — җәзасыз, һичбер җәза күрмичә, җәзага тартылмыйча.

**БЕЗНАКА'ЗАННЫЙ** — җәзасыз, җәзасыз калдырылган, җәза бирелми калган.

**БЕЗНАЧА'ЛИЕ** *ср. книж.* — тәртипсезлек, башбаштаклык; анархия, властьсызлык, власть юклыгы.

**БЕЗНО'ГИЙ** — 1. аяксыз; 2. *(разг. (с больными ногами)* авыру аяклы.

**БЕЗНО'СЫЙ** — *(о человеке)* борынсыз; *(о чайнике)* борынсыз, борыны төшкән.

**БЕЗНРА'ВСТВЕННО** *нареч.* — әдәпсез рәвештә, оятсыз рәвештә.

**БЕЗНРА'ВСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. әхлаксызлык, әдәпсезлек; 2. женси тотнаксызлык, бозыклык.

**БЕЗНРА'ВСТВЕННЫЙ** — 1. әхлаксыз, әдәпсез, оятсыз; 2. бозык, женси тотнаксыз.

**БЕЗО'** *предлог.* — к. без.

**БЕЗОБИ'ДНО** *нареч.* — 1. зарарсыз, зыянсыз; 2. хәтер калдырмаслык итеп.

**БЕЗОБИ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — *(о поступках)* зарарсызлык, зыянсызлык; хәтер калдырмаслык булу; *(о человеке)* юашлык, зарарсызлык.

**БЕЗОБИ'ДНЫЙ** — 1. *(о поступках)* хәтер калдырмаслык, үпкәләмәслек, зарарсыз; 2. *(о человеке)* зарарсыз, юаш, мескен, мәхлук.

**БЕЗО'БЛАЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. болытсызлык; 2. *перен.* тынычлык.

**БЕЗО'БЛАЧНЫЙ** — 1. болытсыз, аяз; 2. *перен.* тыныч, якты.

**БЕЗОБМА'ННЫЙ** — алдаусыз, хыянәтсез, гадел.

**БЕЗОБРА'ЗИЕ** *ср.* 1. *только ед. (уродливость)* гариплек, шыксызлык, ямьсезлек, килбәтсезлек; 2. *(беспорядок)* тәртипсезлек, гауга, тавыш, җәнҗал; 3. *только ед.* юньсезлек, мәгънәсезлек, тәртипсезлек; *что за безобразие!* — бу нинди тәртипсезлек бу!

**БЕЗОБРА'ЗИТЬ** *несов.* — 1. ямьсезләү, бозып тору; 2. *простореч.* к. безобразничать.

**БЕЗОБРА'ЗНИК** *м.*, **БЕЗОБРА'ЗНИЦА** *ж.* — әшәке, кабахәт, оятсыз; тәртипсез, тыйнаксыз.

**БЕЗОБРА'ЗНИЧАТЬ** *несов.* — әшәкеләнү, әшәке кылану; тәртипсезлек итү, тыйнаксызлану, тыйнаксызлык эшләү.

**БЕЗОБРА'ЗНО** *нареч.* — ямьсез, шыксыз, әшәке, юньсез.

**БЕЗОБРА'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(уродливость)* шыксызлык, килбәтсезлек, ямьсезлек, кыяфәтсезлек, гариплек; 2. *(возмутительность)* әшәкелек, кабахәтлек, юньсезлек, тыйнаксызлык.

**БЕЗОБРА'ЗНЫЙ** — 1. *(уродливый)* гарип, шыксыз, килбәтсез, ямьсез, кыяфәтсез; 2. *(возмутительный)* әшәке, кабахәт, юньсез, тыйнаксыз.

**БЕЗОГЛЯ'ДНО** *нареч.* — алдына-артына карамыйча; бик нык бирелеп.

**БЕЗОГОВО'РОЧНО** *нареч.* — берсүзсез, ләм-мим димичә.

**БЕЗОГОВО'РОЧНЫЙ** — берсүзсез, шартсыз, чикләүсез, сылтаусыз, искәрмәсез.

**БЕЗОПА'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет — куркынычсызлык, хәвеф-хәтәрсезлек.

**БЕЗОПА'СНЫЙ** — 1. куркынычсыз, хәвеф-хәтәрсез; *в безопасном месте* — куркынычсыз урында; 2. зарарсыз, зарар-зыян китерми торган; *безопасное средство* — зарарсыз средство.

**БЕЗОРУ'ЖНЫЙ** — 1. коралсыз, кораллланмаган; 2. *перен.* гаҗиз, көчсез; *в этом споре я оказался совершенно безоружным* — бу бәхәстә мин бөтенләй көчсез (гаҗиз) булып калдым.

**БЕЗОСТАНО'ВОЧНО** *нареч.* — туктамыйча, туктамастан, туктаусыз, өзлексез рәвештә.

**БЕЗОСТАНО'ВОЧНЫЙ** — туктаусыз, өзлексез, туктамый торган.

**БЕЗО'СТЫЙ, БЕЗО'СТНЫЙ** *бот.* — кылчыксыз.

**БЕЗОТВЕ'ТНО** *нареч.* — юаш кына, карусыз гына, сүз кайтармыйча.

**БЕЗОТВЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — юашлык, карусызлык, басынкылык, эндәшмәүчәнлек.

**БЕЗОТВЕ'ТНЫЙ** —1. *(не получивший ответа)* җавапсыз; 2. *(безропотный)* юаш, карусыз, басынкы, эндәшмәс, сүз кайтара белми торган.

**БЕЗОТВЕ'ТСТВЕННО** *нареч.*— җавапсыз, җаваплылыкны сизмичә, җаваплылыкны уйламыйча.

**БЕЗОТВЕ'ТСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — җавапсызлык.

**БЕЗОТВЕ'ТСТВЕННЫЙ** —җавапсыз (җаваплылыкны уйламый эш итүче).

**БЕЗОТКА'ЗНО** *нареч.*— тоткарсыз, туктамыйча; *мотор работал безотказно* — мотор тоткарсыз эшләде.

**БЕЗОТКА'ЗНЫЙ** — тоткарсыз, туктаусыз.

**БЕЗОТЛАГА'ТЕЛЬНО** *нареч.*— кичектермичә, кичектермәстән, ашыгыч рәвештә.

**БЕЗОТЛАГА'ТЕЛЬНЫЙ** — кичектергесез, ашыгыч, һич тоткарсыз.

**БЕЗОТЛУ'ЧНО** *нареч.*— өзлексез, беркая китмичә, һәрвакыт, дәвамлы рәвештә.

**БЕЗОТЛУ'ЧНЫЙ** — беркая китми торган; беркая китми...; *безотлучное сиденье дома* — беркая китми өйдә утыру.

**БЕЗОТНОСИ'ТЕЛЬНО** *нареч.*—1. бернәрсәгә дә бәйләмичә; *говоря безотносительно* — бернәрсәгә дә бәйләмичә әйткәндә; 2. карамастан, исәпкә алмастан; *за хранение багажа взимается по 50 коп. с вещи безотносительно к её величине и весу* — багажны саклаган өчен һәр аерым әйбердән, аның зурлыгына һәм авырлыгына карамастан, 50 тиен алына.

**БЕЗОТНОСИ'ТЕЛЬНЫЙ** — һәр очракта да дөрес, абсолют.

**БЕЗОТРА'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — куанычсызлык, юанычсызлык, күңелсезлек, сөенечсезлек.

**БЕЗОТРА'ДНЫЙ** — куанычсыз, юанычсыз, күңелсез, сөенечсез, кайгылы; авыр, караңгы (мәсәлән, тормыш).

**БЕЗОТЧЁТНО** *нареч.* — инстинктив рәвештә, ихтыярсыз рәвештә; контрольсез, контрольсез рәвештә, исәпләп-нитеп тормыйча.

**БЕЗОТЧЁТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. отчётсызлык, контрольсезлек; 2. инстинктивлык, ихтыярсызлык, үз-үзенә хисап бирмичә эшләү.

**БЕЗОТЧЁТНЫЙ** —1. *(не подлежащий контролю)* контрольсез; 2. *(бессознательный)* инстинктив, ихтыярсыз, аңсызлык белән эшләнгән, хисап бирмичә эшләнгән.

**БЕЗОШИ'БОЧНО** *нареч.*— ялгышмыйча, хатасыз, дөрес.

**БЕЗОШИ'БОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — хатасызлык, дөреслек.

**БЕЗОШИ'БОЧНЫЙ** — хатасыз, ялгышсыз, дөрес.

**БЕЗРАБО'ТИЦА** *ж. мн.* нет — эшсезлек, эш юклык, эшкә мохтаҗлык.

**БЕЗРАБО'ТНЫЙ** — эшсез (эш юклыктан), эшсез калган.

**БЕЗРА'ДОСТНО** *нареч.*— күңелсезлек белән, күңелсез.

**БЕЗРА'ДОСТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — шатлыксызлык, күңелсезлек.

**БЕЗРА'ДОСТНЫЙ** — шатлыксыз, күңелсез, куанычсыз, кайгылы, әчпошыргыч.

**БЕЗРАЗДЕ'ЛЬНО** *нареч.*— тулысынча, бөтен килеш, бүлгәләп тормыйча.

**БЕЗРАЗДЕ'ЛЬНЫЙ** —1. бүленми торган; уртак; *безраздельное имущество* — уртак милек; 2. тулы; *безраздельная власть* — тулы власть.

**БЕЗРАЗЛИ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет —1. ваемсызлык, кызыксынмау, салкын караш, дикъкатьсезлек; 2. *устар. (отсутствие различия)* аерма юклык.

**БЕЗРАЗЛИ'ЧНО**—1. *в знач.сказ.* барыбер; *для меня безразлично* — миңа барыбер; 2. *нареч.* ис китмичә; салкын; *он отнёсся ко мне как-то безразлично* —ул миңа ничектер салкын карады (салкын мөнәсәбәт күрсәтте).

**БЕЗРАЗЛИ'ЧНЫЙ** —1. кызыксынусыз, салкын; *безразличный взгляд на вещи* — әйберләргә салкын караш; 2. *(непримечательный)* гади; 3. *спец.* нейтраль, битараф (бер якның да йогынтысына бирелми торган).

**БЕЗРАССВЕ'ТНЫЙ** —1. яктырмас; 2. *перен.* өметсез, шатлыксыз, котылгысыз, караңгы.

**БЕЗРАССУ'ДНО** *нареч.*— уйламыйча.

**БЕЗРАССУ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. безрассудство.

**БЕЗРАССУ'ДНЫЙ** — уйламый эшләнгән, дуамал.

**БЕЗРАССУ'ДСТВО** *ср. мн.* нет — дуамаллык, ахмаклык, акылсызлык; *какое безрассудство — переходить реку по льду во время ледохода* — боз киткән вакытта боздан бозга сикереп елга аркылы чыгу — нинди ахмаклык ул.

**БЕЗРАССУ'ДСТВОВАТЬ** *несов.*— дуамаллану, ахмаклык эшләү.

**БЕЗРАСЧЁТНЫЙ** — исәпсез, хисапсыз, чамасыз; саксыз.

**БЕЗРЕЗУЛЬТА'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — нәтиҗәсезлек.

**БЕЗРЕЗУЛЬТА'ТНЫЙ** — нәтиҗәсез, уңышсыз.

**БЕЗРО'ГИЙ** — мөгезсез, мүкләк.

**БЕЗРО'ДНЫЙ** — туган-тумачасыз, кардәш-ырусыз, нәсел-нәсәпсез; туган иле булмаган; *безродный космополит* — туган иле булмаган космополит.

**БЕЗРО'ПОТНО** *нареч.*— сукранмыйча, зарланмыйча, карышмыйча.

**БЕЗРО'ПОТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. сукранмаучанлык, зарланмаучанлык; 2. буйсынучанлык, юашлык, карышмаучанлык.

**БЕЗРО'ПОТНЫЙ** *книж.*—1. *(не ропщущий)* сукранмаучан, зарланмаучан; 2. *(покорный)* буйсынучан, юаш, карышмаучан, карусыз.

**БЕЗРУКА'ВКА** *ж.*— җиңсез кием.

**БЕЗРУ'КИЙ**—1. кулсыз; 2. *перен.* сәләтсез, булдыксыз.

**БЕЗРЫ'БЬЕ** *ср. мн.* нет — балыксызлык, балык җитмәү. ◇ **На безрыбьи и рак рыба** — ит юкта үпкә тансык.

**БЕЗУБЫ'ТОЧНЫЙ** — зарарсыз, зыянсыз (сәүдә).

**БЕЗУДА'РНЫЙ** *грам.*— басымсыз.

**БЕЗУДЕ'РЖНО** *нареч.*— к. безудержу.

**БЕЗУДЕ'РЖНЫЙ** — тыелгысыз; тоткарсыз; йөгәнсез, дилбегәсез.

**БЕЗУ'ДЕРЖУ** *нареч.*— тыелгысыз рәвештә, тыела алмыйча.

**БЕЗУКОРИ'ЗНЕННО** *нареч.*— бик яхшы, кимчелексез итеп, тел тидермәслек итеп.

**БЕЗУКОРИ'ЗНЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — кимчелексезлек, әйбәт булу, кимчелексез булу.

**БЕЗУКОРИ'ЗНЕННЫЙ** — кимчелексез, әйбәт, яхшы, тел тидермәслек, сүз әйтмәслек.

**БЕЗУ'МЕЦ** *м.*—1. *(безрассудный)* башсыз, акылсыз, дуамал; 2. *устар. (умалишённый)* дивана, тиле, акылдан язган.

**БЕЗУ'МИЕ** *ср. мн.* нет —1. *(безрассудство)* башсызлык, дуамаллык; 2. *устар. (сумасшествие)* акылсызлык, акылдан язганлык.

**БЕЗУ'МНО** *нареч.*—1. ашкынып, шашып, үз-үзен онытып; *любить безумно* — шашып ярату; 2. *перен. разг.* бик, үтә; *безумно холодно* — бик салкын.

**БЕЗУ'МНЫЙ** —1. дуамал, акылга сыймаган, акылга сыймаслык; *безумная отвага*— дуамал батырлык; 2. чиктән тыш, чиксез, соң дәрәҗәдә; *безумная усталость* — чиктән тыш арыганлык; 3. *устар.* акылсыз, шашкан, акылдан язган.

**БЕЗУ'МОЛКУ, БЕЗУ'МОЛЧНО** *нареч.*— туктаусыз, өзлексез, тынмастан.

**БЕЗУ'МОЛЧНЫЙ** *поэт.*— өзлексез, тоташ, туктаусыз, тынмас.

**БЕЗУ'МСТВО** *ср. мн.* нет —1. *(безумный поступок, безумие)* акылсызлык, башсызлык; 2. *(удаль)* батырлык, кыюлык.

**БЕЗУ'МСТВОВАТЬ** *несов.*—1. *(поступать безрассудно)* ахмаклык эшләү, тинтәкләнү; 2. *(бесноваться, бушевать)* ярсу, дулау, ду килү, дуамаллану.

**БЕЗУПРЕ'ЧНО** *нареч.*— бик яхшы итеп, тел тидермәслек итеп, чиста.

**БЕЗУПРЕ'ЧНЫЙ** — бик яхшы, шелтәләмәслек, мактарлык, тел тидермәслек, сүз әйтмәслек.

**БЕЗУРЯ'ДИЦА** *ж. мн.* нет, *простореч.*— тәртипсезлек.

**БЕЗУСЛО'ВНО** *нареч.*—1. һичшиксез, һичсүзсез; *безусловно честный человек* — һичшиксез намуслы кеше; 2. *ввод. сл.* әлбәттә, һичшиксез; *безусловно, он ничего не знал об этом* — әлбәттә, ул бу турыда бернәрсә дә белмәгән.

**БЕЗУСЛО'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет —1. шартсызлык; 2. катгыйлек.

**БЕЗУСЛО'ВНЫЙ** —1. шартсыз, шартлар белән чикләнмәгән, шарт куелмаган; 2. һичсүзсез, берсүзсез; *безусловное повиновение* — һичсүзсез буйсыну.

**БЕЗУСПЕ'ШНО** *нареч.* — файдасызга, әрәмгә, бушка, нәтиҗәсез.

**БЕЗУСПЕ'ШНОСТЬ** *ж. мн.* нет — уңышсызлык, файдасызлык, нәтиҗәсезлек.

**БЕЗУСПЕ'ШНЫЙ** — уңышсыз, файдасыз, әрәм, нәтиҗәсез.

**БЕЗУ'СТАЛИ** *нареч.*— армый-талмый.

**БЕЗУСТА'ННО** *нареч.*— армый-талмый, туктамастан.

**БЕЗУСТА'ННЫЙ** *устар.*— туктаусыз; *не томил я её безустанной работой* — мин аны туктаусыз эш белән ялыктырмадым.

**БЕЗУ'СЫЙ**—1. мыексыз; *безусый мужчина* — мыексыз ир кеше; 2. *перен. фам. пренебр.* яшь, бик яшь; *безусый мальчишка* — яшь малай.

**БЕЗУТЕ'ШНЫЙ** — юанычсыз.

**БЕЗУХА'ННЫЙ** *устар.*— иссез, исен югалткан (чәчәк).

**БЕЗУЧА'СТИЕ** *ср. мн.* нет, **БЕЗУЧА'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ваемсызлык, кызыксынмау, уртаклашмау.

**БЕЗУЧА'СТНЫЙ** — салкын, ваемсыз.

**БЕЗЫЗВЕ'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *устар.*— 1. *(неизвестность)* билгесезлек; 2. *(отсутствие известий)* хәбәрсезлек, хәбәр булмау.

**БЕЗЫЗВЕ'СТНЫЙ** — билгесез, шөһрәтсез, дансыз, танылмаган.

**БЕЗЫМЕ'ННЫЙ, БЕЗЫМЁННЫЙ, БЕЗЫМЯ'ННЫЙ** — исемсез, исеме билгесез, аноним. ◇ **Безымянный палец** — атсыз бармак.

**БЕЗЫСКУ'ССТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — табигыйлек, гадилек.

**БЕЗЫСКУ'ССТВЕННЫЙ** —табигый, гади.

**БЕЗЫСХО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— котылгысызлык, котылгысыз булу, әмәлсезлек.

**БЕЗЫСХО'ДНЫЙ** *книж.*— котылгысыз, әмәлсез, бетмәс.

**БЕКА'С** *м. зоол.*— чуллык, бекас (саз кошы).

**БЕКАСИ'ННИК** *м.*— вак ядрә, бекас ядрәсе.

**БЕКАСИ'НЫЙ** — чуллык...-ы; бекас...-ы; *бекасиное гнездо* — чуллык оясы.

**БЕКЕ'ША** *ж.*— бекеш (арты бөрмәле пальто).

**БЕКО'Н** *м. мн.* нет — бекон (җиңелчә тозланган яки какланган яшь дуңгыз ите).

**БЕ'ЛАЯ ЛИ'ЛИЯ** *бот.*— төнбоек.

**БЕ'ЛАЯ СМО'ЛЕВКА** *бот.*— кәҗә имчәге, сулы имчәк, сукыр чәчәк.

**БЕЛЕНА'** *ж. мн.* нет, *бот.*— тилебәрән орлыгы.

**БЕЛЕНДРЯ'СЫ** *мн. устар.*— буш сүз, сафсата.

**БЕЛЁННЫЙ, БЕЛЁНЫЙ** — агартылган, акка буялган.

**БЕ'ЛЕНЬКАЯ** *в знач. сущ. устар. простореч.*—25 сумлык кәгазь акча.

**БЕ'ЛЕНЬКИЙ** — ак, ак кына, ап-ак.

**БЕЛЕ'СЫЙ, БЕЛЁСЫЙ, БЕЛЕСОВА'ТЫЙ** — аксыл.

**БЕЛЕ'ТЬ** *несов.*—1. *(о белых предметах: виднеться)* агарып күренү, агарып күренеп тору; 2. *(становиться белым)* агару, ак төскә керү; 3. *обл. (рассветать)* таң ату.

**БЕЛЕ'ТЬСЯ** *несов.*— агарып күренү, агарып күренеп тору.

**БЕЛЁХОНЕК, БЕЛЁШЕНЕК** — ап-ак, бөтенләй ак, чиста, пакь.

**БЕЛЁХОНЬКО** *нареч.*— ап-ак итеп.

**БЕЛИБЕРДА'** *ж. мн.* нет — юк-бар сүз, сафсата, мәгънәсез сүз.

**БЕЛИЗНА'** *ж. мн.* нет — аклык, аксыллык.

**БЕЛИ'ЛА** *ед.* нет — 1. ак буяу; 2. *устар.* кершән.

**БЕЛИ'ЛЬНЫЙ** — агарту...-ы; *белильный раствор* — агарту измәсе (эремәсе).

**БЕЛИ'ЛЬНЯ** *ж.*— агарту бүлеге (туку һәм кәгазь фабрикаларында).

**БЕЛИ'ЛЬЩИК** *м.*, **БЕЛИ'ЛЬЩИЦА** *ж.*— буяучы, агартучы, акшарлаучы.

**БЕЛИ'ТЬ** *несов.*— 1. агарту, акка буяу; акшарлау; *белить потолок* —түшәмне агарту; 2. *текст.* агарту, аклау; 3. кершән ягу; *белить лицо* — биткә кершән ягу.

**БЕЛИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. кершән ягыну; 2. *страд.* агартылу, акка буялу, акшарлану.

**БЕ'ЛИЧИЙ** — 1. тиен... -ы; *беличья шкурка* — тиен тиресе; 2. тиен мехыннан тегелгән, тиен...; *беличья шуба* — тиен мехыннан тегелгән тун, тиен тун.

**БЕ'ЛКА** *ж. зоол.*— тиен (җәнлек). ◇ **Вертеться, как белка в колесе** — бер минут та тик тормау; муеннан эшкә чумган булу.

**БЕЛКОВИ'НА** *ж. мн.* нет — аксым.

**БЕЛКО'ВЫЙ** — 1. аксым... -ы; *белковые вещества* — аксым матдәләре; 2. аксымлы; *белковые корма* — аксымлы азыклар.

**БЕЛЛАДО'ННА** *ж. мн.* нет — 1. *бот.* эт җиләге; 2. *мед.* белладонна (эт җиләгеннән ясалган дару).

**БЕЛЛЕТРИ'СТ** *м.*— беллетрист (романнар, хикәяләр, повестьлар һ. б. язучы).

**БЕЛЛЕТРИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — 1. беллетристика, матур әдәбият (проза белән язылган роман, хикәя, повесть һ. б.); матур әдәбият китаплары; 2. *перен. ирон.* фәлсәфә сату; *деловые соображения сменились беллетристикой* — файдалы фикерләр сөйләү урынына фәлсәфә сату башланды.

**БЕЛЛЕТРИСТИ'ЧЕСКИЙ**— беллетристик; *беллетристическое произведение* — беллетристик әсәр.

**БЕЛОБИЛЕ'ТНИК** *м. доревол.*— ак билетлы кеше (сәламәтлеге ягыннан гаскәри хезмәткә ярамаган кеше).

**БЕЛОБОРО'ДЫЙ** — ак сакаллы, чал сакаллы, сакалына чал кергән.

**БЕЛОБРЫ'СЫЙ** — аксыл чәчле, җитен чәчле.

**БЕЛОБРЮ'ШКА** *ж. зоол.*— актүш (кош).

**БЕЛОВА'ТЫЙ** — аксыл.

**БЕЛОВА'Я** *ж.*, **БЕЛОВИ'К** *м.*— аклама, акка (чистага) язылган кульязма.

**БЕЛОВО'Й** — акка язылган, чистага язылган, аклама.

**БЕЛОВОЛО'СЫЙ** — ак чәчле.

**БЕЛОГВАРДЕ'ЕЦ** *м.*, **БЕЛОГВАРДЕ'ЙКА** *ж.*— ак гвардеец, ак гвардиячe; контрреволюционер.

**БЕЛОГВАРДЕ'ЙСКИЙ** — ак гвардиячеләр... -ы; *белогварейский отряд* — ак гвардиячеләр отряды.

**БЕЛОГВАРДЕ'ЙЩИНА** *ж. мн.* нет, *собир. презрит.*— ак гвардиячеләр (советлар властена, эшчеләр һәм крестьяннар дәүләтенә каршы көрәшкән контрреволюцион көчләрнең берсе).

**БЕЛОГОЛО'ВКА** *ж. бот.*— ак тукранбаш.

**БЕЛОГОЛО'ВНИК** *м. бот.*— тәти көпшә.

**БЕЛОГОЛО'ВЫЙ** — ак башлы.

**БЕЛОЗЁМ** *м.*— актуфрак.

**БЕЛОЗУ'БЫЙ** — ак тешле.

**БЕЛО'К** I *м. биол. хим.*— аксым.

**БЕЛО'К** II *м.*—1. *(оболочка глаза)* күз агы; 2. *(яичный)* йомырка агы; *взбить белки* — йомырка агын күпертү. ◇ **Выпучить белки** *просторечю*— күзләрне акайту.

**БЕЛОКА'МЕННАЯ** *в знач. сущ. перен. истор.*— Москва, Мәскәү.

**БЕЛОКОПЫ'ТНИК** *м. бот.*— баялыш, актояк.

**БЕЛОКУ'РЫЙ** — аксыл чәчле.

**БЕЛОЛИ'ЦЫЙ** — ак йөзле, ак чырайлы.

**БЕЛОРО'ЗОВЫЙ** — аксыл ал.

**БЕЛОРУ'С** *м.*— белорус.

**БЕЛОРУСКА** *ж.*— белорус хатын-кызы.

**БЕЛОРУ'ССКИЙ** — белорус... ы; Белоруссия... -ы; *белорусский язык* — белорус теле; *Белорусская республика* — Белоруссия республикасы.

**БЕЛОРУ'СЫ**—белоруслар, белорус халкы.

**БЕЛОРУ'ЧКА** *м.* и *ж.*— аксөяк; эш сөймәүче.

**БЕЛОРУ'ЧНИЧАТЬ** *несов. устар.*— аксөякләнү, авыр эш сөймәү.

**БЕЛОРЫ'БИЙ** — акбалык... ы; *белорыбий жир* — акбалык мае.

**БЕЛОРЫ'БИЦА** *ж.*— акбалык.

**БЕЛОСНЕ'ЖНЫЙ** — ап-ак, кардай ак.

**БЕ'ЛОЧНИК** *м. обл.*— 1. тиен тиреләрен эшкәртүче; 2. тиен аулаучы.

**БЕЛОШВЕ'ЙКА** *ж.*— бельё тегүче.

**БЕЛОШВЕ'ЙНЫЙ** — бельё тегү... -ы; *белошвейная мастерская* — бельё тегү мастерское.

**БЕЛОЭМИГРА'НТ** *м.*—ак эмигрант (эмиграциядә яшәүче контрреволюционер).

**БЕЛОЭМИГРА'НТСКИЙ** — ак эмигрантлар... -ы; *белоэмигрантская газета* — ак эмигрантлар газетасы.

**БЕЛОЭМИГРА'НТЩИНА** *ж. собир.*— ак эмигрантлар (Советлар Россиясеннән качып киткән контрреволюционерлар).

**БЕЛУ'ГА** *ж.*— белуга, кырпы (балык). ◇ **Реветь белугой** — бик каты акырып елау.

**БЕЛУ'ЖИЙ** — белуга... -ы; кырпы...-ы *белужий жир* — белуга мае.

**БЕЛУ'ЖИНА** *ж. мн.* нет — белуга ите, кырпы ите; белуга итеннән хәзерләнгән ашамлык.

**БЕ'ЛЫЙ** — 1. ак; *белый платок* — ак яулык; 2. *полит.* контрреволюцион, ак гвардиячe; *белый офицер* — ак гвардияче офицер; *в знач. сущ., преимущ. мн.* аклар (контрреволюционерлар); 3. ак тәнле; *белая раса* — ак тәнле раса; *в знач. сущ.*

*преимущ.* *мн.* ак тәнләләр. ◇ **Белая горячка** — белая горячка (алкоголикларда була торган авыру). **Белый дом** — Вашингтонда Америка Кушма Штатлары президентының сарае. **Белый свет** — дөнья, якты дөнья, җир йөзе. **Белый уголь** — су көче. **Средь бела дня** — көпә-көндез. **Белые ночи** — ак төннәр. **Белое мясо** — тавык һәм бозау ите. **Довести до белого каления** — бик нык ачуын китерү. **Белые стихи** *лит.*— рифмасыз шигырьләр.

**БЕЛЬ** *ж. обл.*— 1. аклык; 2. *(рыбья чешуя)* балык тәңкәсе; 3. *(сорт яблок)* ак алма.

**БЕЛЬВЕДЕ'Р** *м.*— бельведер, чардак, балкон (бинаның өстендә).

**БЕЛЬГИ'ЕЦ** *м.* — бельгияле.

**БЕЛЬГИ'ЙКА** *ж.*— бельгияле хатын-кыз.

**БЕЛЬГИ'ЙСКИЙ** — Бельгия...-ы; *бельгийское правительство* — Бельгия хөкүмәте.

**БЕЛЬГИ'ЙЦЫ** *мн.*— бельгиялеләр, Бельгия халкы.

**БЕЛЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир.*— кер, бельё; *стирать бельё* — кер юу. ◇ **Нижнее бельё** — күлмәк-штан. **Постельное бельё** — мендәр тышы, җәймә һ. б. **Столовое бельё** — ашъяулык, тастымал һ. б.

**БЕЛЬЕВО'Й** — кер... -ы; *бельевой шкаф*— кер шкафы; *бельевое мыло* — кер сабыны.

**БЕЛЬЕВЩИ'ЦА** *ж.*— 1. керче, бельёчы (торакларда, санаторийларда); 2. бельё тегүче.

**БЕЛЬМЕ'С:** **ни бельмеса не знать** — әлифне таяк дип тә белмәү, бернәрсә дә белмәү (татарча „белмәс" дигән сүздән ясалган).

**БЕЛЬМО'** *ср.*— 1. ак, күзгә төшкән ак; 2. *мн. уничиж. просторечн. обл.* бәбәкләр, күзләр; *чего бельмы выпучил?* — нәрсә син күзләреңне акайттың? ◇ **Как бельмо на глазу** — күзгә төшкән ак шикелле, күзгә кергән чүп шикелле, күз көеге булып.

**БЕЛЬЧО'НОК** *м.* (*мн.* бельчата) — тиен баласы.

**БЕЛЬЭТА'Ж** *м.*— бельэтаж (1. өйнең икенче каты; 2. театрда партердан югары кат).

**БЕЛЯ'К** *м.*— 1. *зоол.* ак куян (кышын йоны агара торган соры куян — үр куянына каршы куелып әйтелә); 2. акбаш (ак күбекле дулкын).

**БЕЛЯ'НА** *ж.*— билән (агач төяп агызу өчен ясалган яссы төпле барка).

**БЕНГА'ЛЬСКИЙ** — Бенгалия... -ы; *бенгальский тигр* — Бенгалия юлбарысы.

**БЕНЕФИ'С** *м.*— бенефис (буржуаз илләрдә — театрда уйнаучыларның берсе файдасына куелган спектакль яки концерт).

**БЕНЕФИ'СНЫЙ** — бенефис... -ы; *бенефисные пьесы* — бенефис пьесалары.

**БЕНЕФИЦИА'НТ** *м.*— бенефициант (бенефисы үткәрелә торган артист).

**БЕНЗИ'Н** *м. мн.* нет — бензин.

**БЕНЗИ'НКА** *ж. разг.*— бензинка (бензин яндыра торган җылыту приборы).

**БЕНЗИ'НОВЫЙ** — бензин... -ы; *бензиновый запах* — бензин исе.

**БЕНУА'Р** *м.* — бенуар (театрда ложаларның түбәнге ярусы).

**БЕРГАМО'Т** *м. бот.*— бергамот (грушаның бер төре).

**БЕРГАМО'ТНЫЙ, БЕРГАМО'ТОВЫЙ** — бергамот... -ы; *бергамотный запах* — бергамот исе.

**БЕРДА'НКА** *ж.*—берданка (мылтык төре).

**БЁРДО** *ср. текст.*— кылыч (туку станогында).

**БЕРДЫ'Ш** *м.*— айбалта (XVI—XVII гасырларда сугыш коралы).

**БЕ'РЕГ** *м.* (*мн. берегá*) — яр, су кырые, су буе.

**БЕРЕГИ'СЬ!** — сак бул! кара! абайлап йөр! аң (уяу) бул!

**БЕРЕГОВО'Й** — яр... -ы, яр буе... -ы; *береговая линия* — яр сызыгы; *береговая фауна* — яр буе хайваннары.

**БЕРЕДИ'ТЬ** *несов. разг.*— 1. авырттыру, борчу (авырткан урынга тиеп); 2. *перен.* ярсыту.

**БЕРЕДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— авырттырылу, борчытылу, ярсытылу (авырткан урын).

**БЕРЕЖЛИ'ВО** *нареч.*— сакчыллык белән.

**БЕРЕЖЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — сакчыллык, саклаучанлык.

**БЕРЕЖЛИ'ВЫЙ** — сакчыл, хәстәрле, саклаучан, сак тотучан.

**БЕ'РЕЖНО** *нареч.*— саклык белән, ипләп кенә, абайлап.

**БЕ'РЕЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(осторожность)* саклык; 2. *(заботливость)* кайгыртучанлык.

**БЕ'РЕЖНЫЙ** — 1. *(осторожный)* сак; 2. *(заботливый)* кайгыртучан.

**БЕРЁЗА** *ж.*— каен.

**БЕРЁЗКА** *ж. бот.*— 1. яшь каен; 2. эт эчәгесе.

**БЕРЁЗНИК** *м. мн.* нет — каенлык, каенсар, каен урманы.

**БЕРЕЗНЯ'К** *м. мн.* нет — 1. к. берёзник; 2. каен чытыры.

**БЕРЁЗОВИК** *м.*— каен гөмбәсе.

**БЕРЁЗОВИЦА** *ж. мн.* нет — каен суы.

**БЕРЁЗОВЫЙ** — 1. каен... -ы; *берёзовый лист* — каен яфрагы; 2. каен...; *берёзовая доска* — каен такта. ◇ **Дать берёзовой каши** *устар.* — чыбыклау, суктыру, чыбык белән яру, чыбык белән кыйнау.

**БЕРЕ'МЕНЕТЬ** *несов.*— йөккә узу, йөккә калу, балага узу, корсакка узу.

**БЕРЕ'МЕННАЯ** — 1. *(о женщине)* йөкле, көмәнле, йөккә узган, буйга узган, авырлы; 2. *(о животных)* буаз.

**БЕРЕ'МЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(о женщине)* йөклелек; 2. *(о животных)* буазлык.

**БЕРЕ'МЯ** *ср. мн.* нет, *простореч. обл.*— бер кочак, бер күтәрәм; *беремя дров* — бер кочак утын. ◇ **Беремя дел** — эш күп, эш муеннан.

**БЕРЕСКЛЕ'Т** *м. бот.*— кабар агачы.

**БЕ'РЕСТ** *м. бот.*— карагач.

**БЕРЕСТА', БЕРЁСТА** *ж. мн.* нет — туз, каен тузы.

**БЕРЕСТЕ'НЬ** *ж.*— тырыс, туз тубал.
**БЕРЕСТО'ВЫЙ, БЕРЕСТЯНО'Й**—1. каен тузы... -ы; *берестовый дёготь* — каен тузы дегете; 2. каен тузыннан ясалган; *берестяные изделия* — каен тузыннан ясалган әйберләр.
**БЕРЕ'Т** *м.*— берет (баш киеме).
**БЕРЕ'ЧЬ** *несов.*— 1. *(хранить)* саклау, сак тоту, саклап тоту; 2. *(щадить, жалеть)* кызгану, аяу, җәлләү; 3. *(не разглашать)* яшереп тоту, сер итеп саклау, саклау.
**БЕРЕ'ЧЬСЯ** *несов.*— 1. *(быть осторожным)* сак булу, саклану; 2. *(остерегаться)* саклану.
**БЕРИ'ЛЛ** *м.* — зәбәрҗәт (асылташ).
**БЕРКЛИА'НСТВО** *ср. мн.* нет — берклианчылык (философиядә реакцион субъектив идеализмның бер төре).
**БЕ'РКОВЕЦ** *м. устар.*— берковец (СССР-да метрик системага күчкәнгә кадәр кулланылган 10 потлык авырлык үлчәве).
**БЕ'РКУТ** *м. зоол.*— бөркет (кош).
**БЕРЛО'ГА** *ж.*— 1. оя, өн (аюның кышлый торган оясы); 2. *перен.* тар, начар торак, начар өй.
**БЕРЛО'ЖНЫЙ** — өндәге, оядагы; кышкы йокыдагы (мәсәлән, аю).
**БЕ'РЦЕ, БЕРЦО'** *ср. устар.*— балтыр, сыйрак, чәлтер.
**БЕРЦО'ВЫЙ** — балтыр... -ы; *берцовая кость* — балтыр сөяге.
**БЕС** *м.* — 1. *рел.* җен, шайтан; 2. *перен.* житез, булдыклы, елдам; 3. *перен.* *(хитрый)* хәйләкәр. ◇ **Рассыпаться мелким бесом** — оста итеп ялагайлану.
**БЕСЕ'ДА** *ж.*— беседа; әңгәмә, сөйләшеп утыру.
**БЕСЕ'ДКА** *ж.*— беседка (бакчада ял итү өчен ясалган түбәсе ябулы урын).
**БЕСЕ'ДОВАТЬ** *несов.*— беседа алып бару; әңгәмә кору, сөйләшеп утыру.
**БЕСЕ'ДЧИК** *м.*— беседа җитәкчесе.
**БЕСЁНОК** *м.* (*мн.* бесенята) — 1. җен баласы; 2. *перен.* шук, шаян.
**БЕСИ'ТЬ** *несов.*— үртәү, ярсыту, ачу китерү, шаштыру.
**БЕСИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *(о животных)* котыру; 2. *перен.* котырыну, шашыну, җилкенү; каты шаяру. ◇ **С жиру беситься** — маена чыдый алмау.
**БЕСКЛА'ССОВЫЙ** — сыйныфсыз, сыйныфларга бүленмәгән.
**БЕСКОЗЫ'РКА** *ж.*— бескозырка, козырёксыз фуражка (матросларның баш киеме).
**БЕСКОНЕ'ЧНО** *нареч.*— 1. чиксез; 2. бик озак.
**БЕСКОНЕ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — очсызкырыйсызлык, чиксезлек, иксез-чиксезлек. ◇ **До бесконечности** — бик озак; *спорить до бесконечности* — бик озак бәхәсләшү.
**БЕСКОНЕ'ЧНЫЙ** — 1. очсыз-кырыйсыз, иксез-чиксез; 2. бик озын, бик озак, бетмәс-төкәнмәс; *бесконечные разговоры* — бетмәс-төкәнмәс сөйләшүләр.
**БЕСКОРЫ'СТИЕ** *ср. мн.* нет — риясызлык, тамгысызлык, хирыссызлык, үзен замаучанлык, эчкерсезлек, үз интересын күзәтмәүчәнлек.
**БЕСКОРЫ'СТНО** *нареч.*— хирыссыз рәвештә, чын күңелдән, үзен аямыйча.
**БЕСКОРЫ'СТНЫЙ** — риясыз, тамгысыз, хирыссыз, эчкерсез.
**БЕСКРА'ЙНИЙ, БЕСКРА'ЙНЫЙ** —очсызкырыйсыз, чиксез.
**БЕСКРО'ВНЫЙ** I — 1. *(без крови)* кансыз, аз канлы; 2. *(бледный)* агарынган, ап-ак; 3. *(без кровопролития)* кан коюсыз.
**БЕСКРО'ВНЫЙ** II — йорт-җирсез, торыр җире юк, тораксыз, сыену урыны булмаган.
**БЕСКРЫ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. канатсызлык; 2. *перен.* иҗади көчсезлек, илһамсызлык.
**БЕСКРЫ'ЛЫЙ** — 1. канатсыз, канаты юк; канаты сынган; 2. *перен.* иҗат көче беткән, иҗади көчсез, илһамсыз.
**БЕСНОВА'ТЫЙ** — тинтәк; җенле.
**БЕСНОВА'ТЬСЯ** *несов.*— котырыну, шашыну, җенләнү, тилерү, юләрләнү.
**БЕСО'ВКА** *ж.*— усал, холыксыз (хатынкыз).
**БЕСО'ВСКИЙ** — шайтан... -ы; *бесовское навождение* — шайтан вәсвәсәсе.
**БЕСПА'МЯТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — хәтерсезлек, онытучанлык.
**БЕСПА'МЯТНЫЙ** — хәтерсез, онытучан.
**БЕСПА'МЯТСТВО** *ср. мн.* нет — 1. һушсызлык; 2. *(исступление)* ярсу, шашыну, үз-үзен белмәү.
**БЕСПАРДО'ННО** *нареч.*— оятсыз рәвештә, оялмыйча, әдәпсез рәвештә.
**БЕСПАРДО'ННЫЙ** — оятсыз, вөҗдансыз, тотнаксыз, тыйнаксыз, әдәпсез, сөмсез, әрсез, пырдымсыз, гарьлексез.
**БЕСПАРТИ'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет — партиясезлек.
**БЕСПАРТИ'ЙНЫЙ** — партиясез, партиядә тормаучы.
**БЕСПЕРЕБО'ЙНО** *нареч.* — туктаусыз, өзлексез, тоткарсыз; туктамыйча.
**БЕСПЕРЕБО'ЙНЫЙ** — 1. туктаусыз, тоткар(лык)сыз; *бесперебойная работа мотора* — моторның тоткарсыз эшләве; 2. өзлексез; *бесперебойный ход строительства* — төзелешнең өзлексез барышы.
**БЕСПЕРЕРЫ'ВНЫЙ** — өзлексез, туктаусыз.
**БЕСПЕРСПЕКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — перспективасызлык.
**БЕСПЕРСПЕКТИ'ВНЫЙ** — перспективасыз.
**БЕСПЕЧА'ЛЬНО** *нареч.*— борчылмыйча, кайгысыз.
**БЕСПЕЧА'ЛЬНЫЙ** — кайгысыз, борчылусыз.
**БЕСПЕ'ЧНО** *нареч.*— 1. гамьсез, ваемсыз; 2. *(халатно)* салкын; *беспечно относиться к делу* — эшкә салкын карау.
**БЕСПЕ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гамьсезлек, ваемсызлык, кайгыртмаучанлык.
**БЕСПЕ'ЧНЫЙ** — 1. гамьсез, ваемсыз, кайгыртмаучан; *беспечный человек* — гамьсез кеше; 2. мәшәкатьсез; *беспечная жизнь* — мәшәкатьсез тормыш; 3. салкын; *преступ-*

*но-беспечное отношение к делу* — эшкә җинаятьчел-салкын караш.

**БЕСПИ'СЬМЕННЫЙ** — 1. язусыз, язуы булмаган, алфавиты булмаган; 2. *устар.* паспортсыз.

**БЕСПЛА'НОВОСТЬ** *ж. мн.* нет — плансызлык.

**БЕСПЛА'НОВЫЙ** — плансыз.

**БЕСПЛА'ТНО** *нареч.*— түләүсез, бушка, бушлай, тиген.

**БЕСПЛА'ТНЫЙ** — түләүсез, буш, тиген.

**БЕСПЛО'ДИЕ** *ср. мн.* нет — 1. тума (нәсел) бирмәү (орлыксызлык, нәселсезлек); 2. *(о почве)* уңдырышсыз булу, уңдырмау.

**БЕСПЛО'ДНО** *нареч.*— бушка, юкка, файдасызга, әрәмгә.

**БЕСПЛО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — нәтиҗәсезлек, уңышсызлык.

**БЕСПЛО'ДНЫЙ** — 1. бала тудыруга сәләтсез, үрчемсез; 2. *(о почве)* уңдырышсыз, уңыш бирми торган; 3. *перен.* файдасыз, файдасызга...; әрәм, нәтиҗәсез; *бесплодные ожидания* — файдасызга көтеп торулар.

**БЕСПОВОРО'ТНО** *нареч.*— катгый рәвештә, тайпылышсыз, борылгысыз.

**БЕСПОВОРО'ТНЫЙ** — катгый, борылгысыз; *бесповоротное решение* — катгый карар.

**БЕСПОДО'БНЫЙ** — тиңсез, тиңдәшсез, чагыштыргысыз.

**БЕСПОЗВОНО'ЧНЫЙ** *зоол.*— умырткасыз, умыртка сөяксез.

**БЕСПОКО'ИТЬ** *несов.* — 1. *(нарушать покой)* борчу, тынычсызлау; мазасызлау, бимазалау; 2. *(мешать)* комачаулау, мәшәкатьләү, борчу; 3. *(внушать тревогу)* хәвефкә төшерү, куркыту.

**БЕСПОКО'ИТЬСЯ** *несов.*— 1. *(волноваться)* борчылу, тынычсызлану; 2. мәшәкатьләнү, борчылу; *не беспокойтесь, мне и так удобно* — мәшәкатьләнмәгез, миңа болай да җайлы.

**БЕСПОКО'ЙНО** *нареч.*— борчылып, тынычсызланып.

**БЕСПОКО'ЙНЫЙ** — 1. *(лишённый покоя)* тынычсыз; борчулы; 2. *(нарушающий спокойствие)* тынгысыз, мәшәкатьле.

**БЕСПОКО'ЙСТВО** *ср.*— тынгысызлык, тынычсызлык, борчылу, мәшәкать.

**БЕСПОЛЕ'ЗНО** *нареч.*— әрәмгә, файдасызга, файдасыз.

**БЕСПОЛЕ'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — файдасызлык.

**БЕСПОЛЕ'ЗНЫЙ** — файдасыз, әрәм; артык; кирәкмәгән.

**БЕСПО'ЛЫЙ** — җенессез; *бесполое размножение* — җенессез үрчү.

**БЕСПОМЕ'СТНЫЙ** *истор.*—поместьесыз, җирсез, биләмәсез (дворян).

**БЕСПО'МОЩНО** *нареч.*— аптыраган хәлдә, аптырап, гаҗизанә, гаҗиз булып.

**БЕСПО'МОЩНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ярдәмчесез булу, ярдәмгә мохтаҗлык; 2. *перен.* көчсезлек.

**БЕСПО'МОЩНЫЙ** — 1. ярдәмчесез, ярдәмгә мохтаҗ; көчсез; 2. *перен.* начар, көчсез (мәсәлән, шигырь).

**БЕСПОРО'ЧНЫЙ** — керсез, кимчелексез, намуслы; *беспорочная служба* — кимчелексез хезмәт.

**БЕСПОРЯ'ДОК** *м.*— 1. *только ед.* тәртипсезлек; 2. *только мн. дореволюц. (волнения)* чуалышлар.

**БЕСПОРЯ'ДОЧНО** *нареч.*— тәртипсез рәвештә.

**БЕСПОРЯ'ДОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(отсутствие порядка)* тәртипсезлек, таркаулык, чуалчыклык; 2. *(непорядочность)* әдәпсезлек, әхлаксызлык, әшәкелек.

**БЕСПОРЯ'ДОЧНЫЙ** — 1. *(хаотический)* тәртипсез, таркау, чуалчык; 2. *(неаккуратный)* җыбалгы, җыйнаксыз; 3. *(непорядочный)* әдәпсез әхлаксыз, әшәке.

**БЕСПО'ЧВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — нигезсезлек, дәлилсезлек.

**БЕСПО'ЧВЕННЫЙ** — нигезсез; дәлилсез, төпсез.

**БЕСПОЩА'ДНО** *нареч.*— аяусыз рәвештә, рәхимсез рәвештә, аямыйча.

**БЕСПОЩА'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — аяусызлык, рәхимсезлек, катылык, шәфкатьсезлек.

**БЕСПОЩА'ДНЫЙ**— аяусыз, рәхимсез, каты, шәфкатьсез.

**БЕСПРА'ВИЕ** *ср. мн.* нет — 1 к. бесправность; 2. *(беззаконие)* законсызлык.

**БЕСПРА'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — хокуксызлык.

**БЕСПРА'ВНЫЙ** — хокуксыз, хокуктан мәхрүм ителгән.

**БЕСПРЕДЕ'ЛЬНО** *нареч.*—1. чиксез рәвештә; 2. *перен.* җан-тән белән.

**БЕСПРЕДЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — чиксезлек, иксез-чиксезлек.

**БЕСПРЕДЕ'ЛЬНЫЙ** — чиксез, иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз.

**БЕСПРЕДМЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — максатсызлык, конкрет түгеллек, эчтәлексез булу.

**БЕСПРЕДМЕ'ТНЫЙ** — эчтәлексез, буш, конкрет булмаган.

**БЕСПРЕКОСЛО'ВНЫЙ** — бәхәссез, каршылыксыз, һичсүзсез.

**БЕСПРЕМЕ'ННО** *нареч. простореч.*—әлбәттә; һичшиксез, котылгысыз.

**БЕСПРЕПЯ'ТСТВЕННО** *нареч.* — тоткарсыз, тоткарлыксыз, тоткарлыкларга очрамыйча, комачаусыз.

**БЕСПРЕПЯ'ТСТВЕННЫЙ** — тоткарсыз, тоткарлыксыз, комачаусыз.

**БЕСПРЕРЫ'ВНО** *нареч.* — өзлексез, тоташтан.

**БЕСПРЕРЫ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — өзлексезлек.

**БЕСПРЕРЫ'ВНЫЙ** — өзлексез, тоташ, туктаусыз.

**БЕСПРЕСТА'ННО** *нареч.* — туктамастан, гел, тынмастан, бертуктамыйча.

**БЕСПРЕСТА'ННЫЙ** — туктаусыз.

**БЕСПРЕЦЕДЕ'НТНЫЙ** — моңарчы булмаган.

**БЕСПРИ'БЫЛЬНЫЙ** — табышсыз, файдасыз, табыш китерми торган.

**БЕСПРИВЕ'ТНО** *нареч.*— салкын чырай белән, караңгы чырай белән.

**БЕСПРИВЕ'ТНЫЙ** — ягымсыз, күңелсез, караңгы.

**БЕСПРИДА'ННИЦА** *ж. устар.* — бирнәсез кыз.

**БЕСПРИЗО'РНИК** *м.*, **БЕСПРИЗО'РНИЦА** *ж.* — тәрбиячесез бала, караучысыз бала, урам баласы.

**БЕСПРИЗО'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. тәрбиячесезлек, караучысызлык; 2. *перен.* ташландыклык, иясезлек.

**БЕСПРИЗО'РНЫЙ** — 1. тәрбиячесез, караучысыз; тәрбиячесе (караучысы) булмаган; *беспризорные дети* — караучысыз балалар; 2. *перен. (заброшенный)* ташландык, иясез.

**БЕСПРИМЕ'РНЫЙ** — тиңсез, тиңдәшсез, охшашы булмаган, тиңдәше булмаган, искиткеч.

**БЕСПРИНЦИ'ПНОСТЬ** *ж. мн.* нет — принципсызлык, тотнаксызлык.

**БЕСПРИНЦИ'ПНЫЙ** — принципсыз, тотнаксыз.

**БЕСПРИСТРА'СТИЕ** *ср.*, **БЕСПРИСТРА'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гаделлек, риясызлык, турылык, бер якны да якламау.

**БЕСПРИСТРА'СТНО** *нареч.* — риясыз рәвештә, гаделлек белән, бер якны да якламыйча.

**БЕСПРИСТРА'СТНЫЙ** — гадел, риясыз, туры.

**БЕСПРИТЯЗА'ТЕЛЬНЫЙ** — тамгысыз, дәгъвасыз.

**БЕСПРИЧИ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — сәбәпсезлек.

**БЕСПРИЧИ'ННЫЙ** — сәбәпсез, сылтаусыз.

**БЕСПРИЮ'ТНЫЙ** — йортсыз-җирсез, торыр җире булмаган, тораксыз, сыенып урыны булмаган.

**БЕСПРОБУ'ДНО** *нареч.* — уянмастан, уянмыйча, каты.

**БЕСПРОБУ'ДНЫЙ** — 1. *(о сне)* уянмас, каты; *беспробудный сон* — уянмас (каты) йокы; 2. *разг. (о пьянице, пьянстве)* туктаусыз, чиктән ашкан.

**БЕСПРО'ВОЛОЧНЫЙ** — чыбыксыз, тимер чыбыксыз.

**БЕСПРОГРА'ММНЫЙ** — программасыз.

**БЕСПРО'ИГРЫШНЫЙ** — оттырышсыз; *беспроигрышный заём* — оттырышсыз заём. ◇ Беспроигрышное дело — ышанычлы эш, һичшиксез унышлы булачак эш.

**БЕСПРОСВЕ'ТНЫЙ** — 1. дөм караңгы, яктырмас; 2. *перен. (лишённый радости)* шатлыксыз, күңелсез, караңгы. ◇ Беспросветное горе — бетмәс-төкәнмәс кайгы.

**БЕСПРОСЫ'ПУ** *нареч.* — 1. уянмастан, тоташ; 2. айнымастан, баш күтәрмичә.

**БЕСПРОЦЕ'НТНЫЙ** — процентсыз.

**БЕСПУ'ТИЦА** *ж. простореч.* — 1. юл өзеклек; 2. *устар.* к. беспорядок.

**БЕСПУ'ТНИК** *м.*, **БЕСПУ'ТНИЦА** *ж.* — азгын, юлдан язган, бозык, бозыклыкка бирелгән.

**БЕСПУ'ТНИЧАТЬ** *несов.* — азгынлану, азгынлык итү, юлдан язу, бозыклыкка бирелү.

**БЕСПУ'ТНЫЙ** — азгын, бозык, бозылган, юлдан язган.

**БЕСПУ'ТСТВО** *ср. мн.* нет — азгынлык, бозыклык.

**БЕСПУ'ТСТВОВАТЬ** *несов.* — к. беспутничать.

**БЕССВЯ'ЗНО** *нареч.* — бәйләнешсез, сүзен сүзгә бәйләмичә.

**БЕССВЯ'ЗНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* бәйләнешсезлек, бәйләнеш юклык; 2. *только мн.* бәйләнешсез сүзләр, мәгънәсез сүзләр; *говорить бессвязности* — бәйләнешсез сүзләр сөйләү.

**БЕССВЯ'ЗНЫЙ** — бәйләнешсез, аңлаешсыз; тәртипсез.

**БЕССЕМЕ'ЙНЫЙ** — семьясыз, буйдак, ялгыз.

**БЕССЕМЯ'НКА** *ж. бот.* — орлыксыз, төшсез җимеш.

**БЕССЕМЯ'ННЫЙ** — 1. орлыксыз, төшсез; 2. чәчүлексез, чәчүлеге юк.

**БЕССЕРДЕ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, **БЕССЕРДЕ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — рәхимсезлек, шәфкатьсезлек, каты күңеллелек, кансызлык.

**БЕССЕРДЕ'ЧНО** *нареч.* — рәхимсез рәвештә, шәфкатьсез рәвештә, рәхимсезлек белән, аямыйча, аямастан.

**БЕССЕРДЕ'ЧНЫЙ** — рәхимсез, шәфкатьсез, каты күңелле, кансыз.

**БЕССИ'ЛИЕ** *ср. мн.* нет — көчсезлек, хәлсезлек.

**БЕССИ'ЛЬНО** *нареч.* — 1. хәлсезләнеп, хәлдән таеп; 2. *перен.* файдасызга.

**БЕССИ'ЛЬНЫЙ** — көчсез, хәлсез, егәрсез.

**БЕССИСТЕ'МНО** *нареч.* — системасыз (рәвештә), плансыз (рәвештә).

**БЕССИСТЕ'МНОСТЬ** *ж. мн.* нет — системасызлык, тәртипсезлек, плансызлык.

**БЕССИСТЕ'МНЫЙ** — системасыз, тәртипсез, плансыз.

**БЕССЛА'ВИЕ** *ср. мн.* нет — хурлык, яман ат.

**БЕССЛА'ВИТЬ** *несов.* — хурлау, яманлау, яман атын сату.

**БЕССЛА'ВИТЬСЯ** *несов.* — 1. хурлыкка төшү; 2. *страд.* хурлыкка төшерелү, яман аты сатылу.

**БЕССЛА'ВНО** *нареч.* — хурлыклы рәвештә.

**БЕССЛА'ВНЫЙ** — хурлыклы, данлыксыз, кадерсез.

**БЕССЛЕ'ДНО** *нареч.* — эзсез, эзсез-нисез, хәбәрсез, хәбәрсез-нисез.

**БЕССЛЕ'ДНЫЙ** — эзсез, хәбәрсез, эзсез-хәбәрсез, бөтенләйгә; *бесследное исчезновение* — бөтенләйгә югалу, эзсез-хәбәрсез югалу.

**БЕССЛОВЕ'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. телсезлек, сөйләүдән мәхрүмлек; 2. карусызлык, буйсынучанлык.

**БЕССЛОВЕ'СНЫЙ** — 1. *(о животных)* телсез, сөйләшүгә сәләтсез, сөйләүдән мәхрүм; 2. *(молчаливый)* аз сүзле, сүзсез, карусыз, телсез-тешсез, эндәшмәс; 3. *ирон. (лицемерно-смиренный)* ялагайланып буйсынучан, ялагайланып ярарга тырышучан.

**БЕССМЕ'ННО** *нареч.* — тоташтан, алмашсыз; *он прослужил бессменно девять лет* — ул тоташтан тугыз ел хезмәт итте.

**БЕССМЕ'РТИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *рел.* мәңгелек, мәңге яшәү; 2. мәңгелек дан.

**БЕССМЕ'РТНИК** *м. бот.* — үлмәс гөл (корыгач та чәчәге сулмый торган гөл).

**БЕССМЕ'РТНЫЙ** — 1. *рел.* үлмәс, үлми торган; 2. мәңгелек, мәңге онытылмас; *бессмертная слава* — мәңгелек дан.

**БЕССМЫ'СЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — мәгънәсезлек, бәйләнешсезлек, бәйләнешсез булу.

**БЕССМЫ'СЛЕННЫЙ** — 1. мәгънәсез, бәйләнешсез; ахмак; *бессмысленный набор слов* — мәгънәсез сүзләр җыелмасы; *бессмысленный взгляд* — ахмак караш; 2. акылга утырмаган; *бессмысленный ребёнок* — акылга утырмаган бала.

**БЕССМЫ'СЛИЦА** *ж.* — 1. мәгънәсез сүзләр, буш сүзләр; бәйләнешсез сүзләр; 2. *(нелепость, вздор)* мәгънәсезлек, ахмаклык.

**БЕССНЕ'ЖНЫЙ** — карсыз; аз карлы.

**БЕССО'ВЕСТНО** *нареч.* — оятсыз рәвештә, вөҗдансыз рәвештә, күзгә карап. ◇ **Бессовестно мало** — бик аз.

**БЕССО'ВЕСТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — вөҗдансызлык, намуссызлык, оятсызлык.

**БЕССО'ВЕСТНЫЙ** — вөҗдансыз, намуссыз, оятсыз.

**БЕССОДЕРЖА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — эчтәлексезлек, мәгънәсезлек.

**БЕССОДЕРЖА'ТЕЛЬНЫЙ** — эчтәлексез, мәгънәсез, кызыксыз, буш; *бессодержательная книга* — эчтәлексез (кызыксыз) китап; *бессодержательный человек* — буш кеше.

**БЕССОЗНА'ТЕЛЬНО** *нареч.* — аңсыздан, белештермичә, үзеннән-үзе.

**БЕССОЗНА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — аңсызлык.

**БЕССОЗНА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. һушсыз, аңын югалткан; 2. *(безотчётный)* аңсыз, белештермичә эшләнгән; 3. *простореч. (несознательный)* аңсыз.

**БЕССО'ННИЦА** *ж.* — йокысызлык, йоклый алмау.

**БЕССО'ННЫЙ** — йокысыз.

**БЕССОЮ'ЗНЫЙ** *лингв.* — теркәгечсез.

**БЕССПО'РНО** *нареч.* — шиксез, һичшиксез.

**БЕССПО'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. бәхәссезлек, ачыклык; 2. дәгъвасызлык, дәгъвасыз булу.

**БЕССПО'РНЫЙ** — 1. шөбһәсез, шиксез, ачык, ап-ачык, бәхәссез; *бесспорная истина* — ап-ачык хакыйкать; 2. дәгъвасыз; *бесспорное право* — дәгъвасыз хокук.

**БЕССРЕ'БРЕННИК** *м.*, **БЕССРЕ'БРЕННИЦА** *ж.* — тамгысыз, хирыссыз, акчага сатылмас кеше, акчага исе китмәүчән.

**БЕССРО'ЧНЫЙ** — сроксыз, срогы чикләнмәгән.

**БЕССТРА'СТИЕ** *ср. мн.* нет — 1. рух тынычлыгы; 2. дәртсезлек.

**БЕССТРА'СТНО** *нареч.* — дәртсез (генә), салкын кан белән, тыныч (кына).

**БЕССТРА'СТНЫЙ** — дәртсез, тыныч, салкын канлы.

**БЕССТРА'ШИЕ** *ср. мн.* нет — куркусызлык, кыюлык, батырлык, йөрәклелек.

**БЕССТРА'ШНО** *нареч.* — курыкмыйча, кыю, кыю рәвештә.

**БЕССТРА'ШНЫЙ** — куркусыз, кыю, батыр.

**БЕССТЫ'ДНИК** *м.*, **БЕССТЫ'ДНИЦА** *ж.* — оятсыз, әдәпсез, инсафсыз, битсез, җир бит.

**БЕССТЫ'ДНИЧАТЬ** *несов.* — оятсызлану, әдәпсезләнү.

**БЕССТЫ'ДНО** *нареч.* — оятсыз рәвештә, әдәпсез рәвештә, тартынмыйча, күзгә карап.

**БЕССТЫ'ДНЫЙ** — оятсыз, әдәпсез, инсафсыз.

**БЕССТЫ'ДСТВО** *ср. мн.* нет — оятсызлык, әдәпсезлек, инсафсызлык.

**БЕССТЫ'ЖИЙ** *простореч.* — үтә оятсыз.

**БЕССЧЁТНЫЙ** — исәпсез, исәпсез-хисапсыз, бик күп.

**БЕСТ** *м.*: **засесть (сесть) в бест** — эзәрлекләүдән качу.

**БЕСТА'КТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тотнаксызлык, сөмсезлек, әрсезлек; урынсызлык.

**БЕСТА'КТНЫЙ** — 1. тотнаксыз, әрсез, сөмсез; *бестактный человек* — әрсез кеше; 2. урынсыз, килешсез; *бестактный поступок* — урынсыз кыланыш.

**БЕСТАЛА'ННЫЙ** I — талантсыз, булдыксыз, сәләтсез.

**БЕСТАЛА'ННЫЙ** II — бәхетсез, бичара.

**БЕ'СТИЯ** *ж.* — әрсез, алдакчы, хәйләкәр, эт (кеше турында).

**БЕСТОВА'РЬЕ** *ср. мн.* нет — товарсызлык, товар җитешмәү, товар юклык.

**БЕСТОЛКО'ВО** *нареч.* — мәгънәсез, юньсез, рәтсез.

**БЕСТОЛКО'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — аңгыралык, мингерәүлек, мәгънәсезлек, рәтсезлек.

**БЕСТОЛКО'ВЩИНА** *ж. мн.* нет — тәртипсезлек, чуалчыклык, буталчыклык.

**БЕСТОЛКО'ВЫЙ** — аңгыра, мингерәү, мәгънәсез, рәтсез, юньсез.

**БЕ'СТОЛКУ** *нареч.* — бушка, файдасызга, юкка.

**БЕ'СТОЛОЧЬ** *ж. мн.* нет — 1. *к.* бестолковщина; 2. аңгыра, мингерәү.

**БЕСТРЕ'ПЕТНО** *нареч.* — тыныч (кына), каушамыйча, курыкмыйча.

**БЕСТРЕ'ПЕТНЫЙ** — куркусыз, кыю, батыр.

**БЕСФО'РМЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — формасызлык.

**БЕСФО'РМЕННЫЙ** — формасыз, чуалчык.

**БЕСХАРА'КТЕРНОСТЬ** *ж. мн.* нет — йомшак характерлылык, аумакайлык.

**БЕСХАРА'КТЕРНЫЙ** — 1. йомшак характерлы, аумакай; 2. *устар.* төссез, күренексез.

**БЕСХВО'СТЫЙ** — 1. койрыксыз; 2. *только мн. зоол.* койрыксызлар (мәсәлән, бакалар).

**БЕСХИ'ТРОСТНОСТЬ** *ж. мн.* нет—**1.** хәйләсезлек, беркатлылык; **2.** гадилек.

**БЕСХИ'ТРОСТНЫЙ** — **1.** хәйләсез, эчкерсез, беркатлы, туры күңелле; *бесхитростный человек* — беркатлы кеше; **2.** гади; *бесхитростный рассказ* — гади хикәя.

**БЕСХЛЕ'БЬЕ** *ср.*— икмәк җитешмәү, ачлык, кытлык.

**БЕСХОЗЯ'ЙСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет— хуҗасызлык; тәртипсезлек (хуҗалыкта).

**БЕСХОЗЯ'ЙСТВЕННЫЙ** — **1.** хуҗалыкны алып бара белми торган, йорт көтә белми торган; *бесхозяйственный человек* — хуҗалыкны алып бара белми торган кеше; **2.** тәртипсез; *бесхозяйственное ведение дела* — эшне тәртипсез алып бару; **3.** хуҗаларча булмаган; *бесхозяйственное отношение к имуществу* — милеккә хуҗаларча булмаган мөнәсәбәт.

**БЕСХРЕБЕ'ТНЫЙ** — принципсыз, тотнаксыз, йомшак.

**БЕСЦВЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** төссезлек; **2.** *перен.* гадилек, күренексезлек.

**БЕСЦВЕ'ТНЫЙ** — **1.** төссез, буяусыз; **2.** *перен.* күренексез, гади.

**БЕСЦЕ'ЛЬНО** *нареч.*— файдасызга, әрәмгә, бушка, юкка.

**БЕСЦЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** максатсызлык; **2.** файдасызлык.

**БЕСЦЕ'ЛЬНЫЙ** — **1.** максатсыз; **2.** *(бесполезный)* файдасыз, буш.

**БЕСЦЕ'ННЫЙ** — **1.** *(очень ценный)* бик кыйммәтле, бәя биреп бетергесез; **2.** *перен. (милый, дорогой)* сөекле, кадерле; **3.** *устар. (не имеющий никакой цены)* бәясез, арзанлы. ◇ **Бесценная посылка** — бәясе күрсәтелмәгән посылка.

**БЕСЦЕ'НОК: за бесценок** — юк бәягә, юк хакка, бик арзанга, шалкан бәясенә.

**БЕСЦЕРЕМО'ННО** *нареч.*— тупас рәвештә, дорфа рәвештә, тартынмыйча, күзгә карап.

**БЕСЦЕРЕМО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** *(развязность)* тупаслык, дорфалык; **2.** *(отсутствие натянутости)* тәкәллефсезлек, тартынусызлык.

**БЕСЦЕРЕМО'ННЫЙ** — **1.** *(развязный)* тупас, дорфа; **2.** *(чуждый церемонности)* тәкәллефсез, тартынусыз.

**БЕСЧЕЛОВЕ'ЧНО** *нареч.*— рәхимсез рәвештә, аямыйча, аямастан, кансызлык белән.

**БЕСЧЕЛОВЕ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — кешелексезлек, шәфкатьсезлек, рәхимсезлек, аяусызлык, кансызлык.

**БЕСЧЕЛОВЕ'ЧНЫЙ** — кешелексез, рәхимсез, шәфкатьсез, аяусыз, кансыз, каты күңелле, таш күңелле.

**БЕСЧЕ'СТИТЬ** *несов.* — хур итү, яман атын сату.

**БЕСЧЕ'СТИТЬСЯ** *несов. страд.* — хур ителү, яман аты сатылу.

**БЕСЧЕ'СТНО** *нареч.*— вөҗдансыз рәвештә.

**БЕСЧЕ'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — намуссызлык, вөҗдансызлык, инсафсызлык.

**БЕСЧЕ'СТНЫЙ** — намуссыз, вөҗдансыз, турылыксыз, инсафсыз.

**БЕСЧЕ'СТЬЕ** *ср. мн.* нет — хурлык, мәсхәрәлек.

**БЕСЧИ'ННЫЙ** *устар.*— әдәпсез, тәртипсез (кеше турында).

**БЕСЧИ'НСТВО** *ср.*— тәртип бозу, җәнҗал, гауга, башбаштаклык.

**БЕСЧИ'НСТВОВАТЬ** *несов.* — тәртип бозу, җәнҗал кубару, гауга чыгару.

**БЕСЧИ'СЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — исәпсез-хисапсызлык, исәпсез-хисапсыз күп булу.

**БЕСЧИ'СЛЕННЫЙ** — сансыз, исәпсез-хисапсыз; санап бетергесез, бихисап, бик күп.

**БЕСЧУ'ВСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** тойгысызлык, сизмәүчәнлек; **2.** рәхимсезлек, каты күңеллелек.

**БЕСЧУ'ВСТВЕННЫЙ** — **1.** тойгысыз, тойгысын югалткан; **2.** *(жестокий)* каты күңелле, рәхимсез, кырыс.

**БЕСЧУ'ВСТВИЕ** *ср. мн.* нет — **1.** *(обморочное состояние)* һушсызлык, һуштан язу; **2.** *(отсутствие чуткости)* салкын карау, салкынлык; рәхимсезлек, катылык.

**БЕСШАБА'ШНОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** *(беспечность)* гамьсезлек, тәртипсезлек; **2.** *(отчаянность)* башсызлык, чаялык.

**БЕСШАБА'ШНЫЙ** *разг.* — **1.** *(беспечный)* гамьсез, тәртипсез; **2.** *(отчаянный)* башсыз, тыңгысыз, чая.

**БЕСШУ'МНО** *нареч.* — тавышсыз, тын, тавышсыз-нисез.

**БЕСШУ'МНЫЙ** — тавышсыз, тавышсызтынсыз, шау-шусыз, тын, тыныч.

**БЕТО'Н** *м. мн.* нет — бетон (цемент массасының ком һәм вакланган таш белән кушылмасы).

**БЕТОНИ'РОВАТЬ** *несов.* — бетонлау.

**БЕТОНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— бетонлану.

**БЕТО'ННЫЙ** — **1.** *бетон...-ы; бетонная масса* — бетон массасы; **2.** *бетон...; бетоннан ясалган; бетонный пол* — бетон идән.

**БЕТОНОМЕША'ЛКА** — бетон изгеч, бетон болгаткыч.

**БЕТО'НЩИК** *м.* — бетонщик, бетончы, бетон коючы.

**БЕЧЕВА'** *ж. мн.* нет — аркан, юан бау.

**БЕЧЁВКА** *ж.*— бау.

**БЕ'ШЕНАЯ ВИ'ШНЯ** *бот.*— эт җиләге.

**БЕ'ШЕНО** *нареч.* — **1.** котырып, котырынып; **2.** *разг. (очень сильно)* кирәгеннән артык, бик каты.

**БЕ'ШЕНСТВО** *ср. мн.* нет — **1.** *(болезнь)* котыру, котыру авыруы; **2.** *(сильное раздражение)* котырыну, ярсу, каты ачулану.

**БЕ'ШЕНЫЙ** — **1.** котырган; *бешеная собака* — котырган эт; **2.** ярсулы, котырынулы; *бешеная атака* — ярсулы атака; **3.** котырынкы, тыелгысыз, кызу; *бешеный характер* — тыелгысыз характер; **4.** чиктән тыш зур; гадәттән тыш зур; *бешеная сила* — чиктән тыш зур көч; *бешеный темп* — гадәттән тыш зур темп. ◇ **Бешеные цены** — чиктән тыш югары бәяләр. **Бешеные день-**

ги — җилдән килгән акча, бик җиңел табылган акча.

**БИШМЕ'Т** *м.* — бишмәт.

**БИБЛИО'ГРАФ** *м.* — библиограф (библиография белгече).

**БИБЛИОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — библиографик, библиография... -ы; *библиографический указатель* — библиографик күрсәткеч; *библиогрфический кабинет* — библиография кабинеты. ◇ **Библиографическая редкость** — бик сирәк очрый торган китап.

**БИБЛИОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — библиография (1. китапларның эчтәлеге һәм тышкы оформлениесе турында критик язма; 2. берәр мәсьәләгә карата төзелгән китаплар, мәкаләләр исемлеге; 3. журналның яки газетаның яңа чыккан китапларга рецензия язып бара торган бүлеге).

**БИБЛИОМА'Н** *м.* — китаплар һәвәскәре китаплар җыю белән мавыгучы).

**БИБЛИОМА'НИЯ** *ж. мн.* нет — библиомания (китаплар җыю белән мавыгу).

**БИБЛИОТЕ'КА** *ж.* — библиотека, китапханә көтепханә.

**БИБЛИОТЕ'КАРСКИЙ** — библиотекарлык... -ы; *библиотекарская должность* — библиотекарлык вазифасы.

**БИБЛИОТЕ'КАРЬ** *м.* — библиотекарь.

**БИБЛИОТЕКОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — библиотека белеме (библиотека эшен оештыру, аны алып бару формалары һәм методлары турындагы фән).

**БИБЛИОТЕ'ЧНЫЙ** — библиотека... -ы- *библиотечный каталог* — библиотека каталогы.

**БИБЛИОФИ'Л** *м.* — библиофил, китаплар сөюче, китаплар һәвәскәре (сирәк очрый торган кыйммәтле китаплар җыюга һәвәс кеше).

**БИБЛИОФИ'ЛЬСКИЙ** — библиофиллык... -ы; библиофиллар... -ы; *библиофильская натура* — библиофиллык табигате; *библиофильский кружок* — библиофиллар түгәрәге.

**БИБЛИОФИ'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — китаплар сөю, китапларга һәвәслек.

**БИ'БЛИЯ** *ж.* — тәүрат (яһүдиләрнең һәм христианнарның дини китабы).

**БИВА'К** *м.* — бивак (гаскәрнең куну яки ял итү өчен ачык һавада тукталыш ясавы).

**БИ'ВЕНЬ** *м.* — казык теш, һөҗүм теше, бәрмәтеш (мамонт, фил, мөгезборын кебек җәнварларда).

**БИВУА'К** *м.* — к. бивак.

**БИДО'Н** *м.* — бидон (капкачлы калай савыт).

**БИЕ'НИЕ** *ср.* — тибү, сугу (йөрәк, пульс турында).

**БИ'ЗНЕС** *м.* — бизнес, эре сәүдә, зур табышлы эш; биржа сәүдәсе (төрле пычрак юллар белән табыш алу).

**БИЗНЕСМЕ'Н** *м.* — бизнесмен (эре сәүдәгәр, биржа сәүдәгәре, табыш артыннан куучы, теләсә нинди эшәке юллар белән зур табыш алучы).

**БИЗО'Н** *м. зоол.* — бизон (Америкада кыргый үгез).

**БИЛЕ'Т** *м.* — билет. ◇ **Кредитный билет** — кәгазь акча.

**БИЛЕТЁР** *м.*, **БИЛЕТЁРША** *ж.* — билет тикшерүче (мәсәлән, театрларда).

**БИЛЕ'ТНЫЙ** — билет... -ы; *билетная касса* — билет кассасы.

**БИЛЛИА'РД, БИЛЛИА'РДНЫЙ** — к. бильярд, бильярдный.

**БИЛЛИО'Н** *м. мат.* — биллион (бер миллиард, кайбер илләрдә мең миллиард).

**БИЛЬДАППАРА'Т** *м. тех.* — бильдаппарат, рәсем тапшыргыч аппарат (рәсемнәрне, язуларны телеграф аша тапшыру аппараты).

**БИЛЬЯ'РД** *м.* — бильярд.

**БИЛЬЯ'РДНАЯ** — бильярд бүлмәсе.

**БИЛЬЯ'РДНЫЙ** — бильярд...-ы; *бильярдный шар* — бильярд шары.

**БИНО'КЛЬ** *м.* — бинокль (ерактагы әйберне якынайтып күрсәтә торган оптик прибор).

**БИНТ** *м.* — бинт, бәйләвеч (яра бәйләү өчен).

**БИНТОВА'ТЬ** *несов.* — бинтлау, бинт белән бәйләү.

**БИНТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — бинтлану, бинт белән бәйләнү.

**БИНТОВО'Й** — бинт... -ы; *бинтовой материал* — бинт материалы.

**БИО'ГРАФ** *м.* — биограф (1. кемнең дә булса биографиясен төзүче; 2. кинематографка кадәр булган киноаппарат төре).

**БИОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — биографик; *биографический очерк* — биографик очерк.

**БИОГРА'ФИЯ** *ж.* — биография, тәрҗемәи хәл.

**БИО'ЛОГ** *м.* — биолог (биология белгече, галиме).

**БИОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — биологик, биология... -ы; *биологический институт* — биология институты.

**БИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — биология (органик дөньяны (тере табигатьне) өйрәнә торган фәннәр комплексы).

**БИОСТА'НЦИЯ** *ж.* — биостанция, биология станциясе (билгеле бер урындагы хайваннарның һәм үсемлекләрнең биологиясен өйрәнү станциясе).

**БИОСФЕ'РА** *ж. мн.* нет — биосфера (җир шары өстендә тереклек таралу өлкәсе).

**БИОФИ'ЗИКА** *ж. мн.* нет — биофизика (биологиянең бер бүлеге; организмнарда була торган күренешләрне ачуда физика законнарын куллана торган фән).

**БИОХИМИ'ЧЕСКИЙ** — биохимия... -ы; биохимик; *биохимический институт* — биохимия институты; *биохимический процесс* — биохимик процесс.

**БИОХИ'МИЯ** *ж. мн.* нет — биохимия (тере организмнарның химик составын һәм организмнарда бара торган химик процессларны өйрәнә торган фән).

**БИПЛА'Н** *м.* — биплан (асы-өсле ике канатлы самолёт).

**БИ'РЖА** *ж.* — биржа (1. капиталистик илләрдә — эре сәүдә һәм финанс эшендә акцияләр һ. б. кыйммәтле кәгазьләр белән

алыш-биреш итү турында килешүләр төзү урыны; 2. *устар.* шәһәр урамнарында извозчикларның җыелып тора торган урыны). ◇ **Чёрная биржа** — кара биржа (чит ил валютасы белән яшерен сәүдә). **Биржа труда** — хезмәт биржасы (капитализм шартларында эшчеләрне яллаганда эшче белән предприниматель арасында арадашлык итүче учреждение).

**БИРЖЕВИ'К** *м.* — биржевик, биржачы (капиталистик илләрдә).

**БИРЖЕВО'Й** — биржа... -ы; *биржевой оборот* — биржа обороты.

**БИ'РКА** *ж.* — бирка, тамга (атларның ялларына һәм товарларга тагыла торган тамга).

**БИРЮЗА'** *ж. мн.* нет — фирәзә (асылташ).

**БИРЮЗО'ВЫЙ** — 1. фирәзә...; *бирюзовый перстень* — фирәзә йөзек; 2. фирәзә төсле; зәңгәр, алсу; *бирюзовые глаза* — зәңгәр күзләр.

**БИРЮ'К** *м. разг.* — 1. ялгыз бүре; 2. *перен.* караңгы чырайлы, ялгызлыкны яратучы кеше. ◇ **Смотреть бирюком** *разг.* — караңгы чырай күрсәтү.

**БИРЮ'ЛЬКИ** *мн.* — шырпы тартыш уены. ◇ **Играть в бирюльки** — юкны бушка аудару, юк-бар белән шөгыльләнү.

**БИРЮ'Ч** *м. истор.* — хәбәрче (борынгы Россиядә хәбәр таратып йөрүче).

**БИРЮ'ЧИЙ** — бүре... -ы; *бирючья нора* — бүре өне (оясы).

**БИРЮ'ЧИНА** *ж. бот.* — бүрекүз, бүре җиләге, мордар агачы.

**БИС!** *межд.* — бис! (театрда „кабатла! тагын бер кат!“ мәгънәсендә тамашачылар тарафыннан әйтелә торган сүз).

**БИ'СЕР** *м. мн.* нет — сәйлән (бизәү өчен кулланыла торган төрле төстәге вак пыяла төймәләр). ◇ **Писать бисером** — тигез һәм бик вак хәрефләр белән язу. **Метать бисер перед свиньями** *ирон.* — юләргә акыл сату.

**БИ'СЕРИНА, БИ'СЕРИНКА** *ж.* — сәйлән бөртеге.

**БИ'СЕРНЫЙ** — 1. сәйлән белән бизәлгән; *бисерный кисет* — сәйлән белән бизәлгән янчык; 2. *перен.* бик вак; *бисерный почерк* — бик вак язу.

**БИСИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — биска чыгу, икенче кат башкару (тамашачыларның соравы буенча кабаттан җырлау, музыка уйнау яки бию).

**БИСИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — биска чыгарылу.

**БИСКВИ'Т** *м.* — бисквит (1. печеньеның бер төре; 2. *тех.* ике тапкыр яндырылган, ялтыравык (глазурь) белән капланмаган фарфор әйбер).

**БИСКВИ'ТНЫЙ** — бисквит...; *бисквитное печенье* — бисквит печенье.

**БИССЕКТРИ'СА** *ж. мат.* — биссектриса (почмакны ике тигез өлешкә бүлә торган туры сызык).

**БИТА'** *ж.* — сага, аткый, атабай, бура таягы (кузна, бура сугу уеннарында кузналарга, шакмакларга төбәп ыргыту өчен кулланыла).

**БИ'ТВА** *ж.* — сугыш, каты сугыш; хәлиткеч сугыш.

**БИТКИ'** *мн.* — битки (чабылган иттән ясалган котлет).

**БИТКО'М**: **битком набить** — шыгрым тутыру, дыңгычлап тутыру; **битком набит (набита, набито)** — шыгрым тулы, дыңгычлап тутырылган, туп-тулы.

**БИТО'К** *м.* — к. бита́.

**БИ'ТЫЙ** — 1. *(избитый)* кыйналган, тукмалган; 2. *(о заколотом скоте)* суелган; 3. *(побеждённый)* җиңелгән, кыйналган; 4. *(разбитый)* ватылган; 5. *(измельченный)* вакланган; 6. атып төшерелгән; суелган; *битая птица* — атып төшерелгән кош, суелган кош. ◇ **Битый час** — бер сәгать буена, озак. **Битая дорога** — такыр юл. **Битые разговоры** — күп чәйнәлгән сүзләр.

**БИТЬ** *несов.* — 1. *(наносить удары)* бәрү, кыйнау, сугу, ору, кагу; 2. *(резать скот)* сую, чалу, бугазлау; 3. *(побеждать)* җиңү, кыйнау; 4. атып төшерү; *он бьёт птицу на лету* — ул кошны очып барганда атып төшерә; 5. ату; *винтовка бьёт хорошо* — винтовка яхшы ата; 6. алу, тидерү, бәрү; *винтовка бьёт на несколько километров* — винтовка берничә километрдан ала (тидерә, бәрә); 7. вату, ваклау; *бить посуду* — савыт-саба вату; *бить щебень* — таш ваклау; 8. бәреп чыгу, чаптырып агу, ургу; *бьёт фонтан* — фонтан бәреп чыга, ургый; *кровь бьёт* — кан чаптырып ага; 9. сугу; *часы бьют десять* — сәгать унны суга. ◇ **Бить масло** — май язу, май атлау. **Бить шерсть** — йон язу, йон тетү. **Бить карту** — басу, ябу, сугып алу. **Бить баклуши** — тырай тибү (тик йөрү). **Бьёт по карману** — кесәгә суга (зарар китерә). **Жизнь бьёт ключом** — тормыш кайнап тора. **Бить в глаза** — күзгә бәрелеп тору, күзгә ташлану. **Бить челом** *устар.* — үтенеп сорау. **Бить тревогу** — тревога күтәрү. **Бить в цель** — туры бәрү, максатка ирешү. **Мне било 17 лет** — миңа 17 яшь тулды. **Бить наверняка** *разг.* — туры бәрү, белеп эш итү. **Бить отбой** *перен.* — фикердән кире кайту, чигенү. **Лихорадка его бьёт** — аны бизгәк тота. **Бить в ладоши** — кул чабу.

**БИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *(драться)* сугышу, кыйнашу; 2. көрәшү; *биться за первенство* — беренчелек өчен көрәшү; 3. бәрелү, сугылу; *биться о стену* — стенага бәрелү; *птица бьётся о стекло* — кош пыялага бәрелә; 4. тибү, сугу, кагу; *сердце бьётся* — йөрәк тибә; 5. көч кую, тырышу, азаплану; *биться над разрешением вопроса* — мәсьәләне чишәргә тырышу, көч кую; *дрова сырые, целый час бьюсь с растопкой* — утын чи, сәгать буена яндырырга азапланам; 6. ватылу, уалу; *посуда часто бьётся* — савыт-саба еш ватыла. ◇ **Биться, как рыба об лёд** — файдасызга тырышу, әрәмгә интегү; зур мохтаҗлыкта яшәү. **Биться об заклад** — бәхәс-

ләшү. **Биться из-за куска хлеба** — ачлы-туклы тору.

**БИТЮ'Г** *м.* — йөк аты.

**БИФШТЕ'КС** *м.* — бифштекс (кыздырып пешерелгән ит кисәге).

**БИ'ЦЕПС** *м.* — бицепс, ике башлы мускул.

**БИЧ** *м.* — 1. озын камчы, чыбыркы; 2. *перен.* бәла, каза, афәт.

**БИЧЕВА'** *ж.* — к. бечева.

**БИЧЕВА'ТЬ** *несов.* — 1. камчылау, чыбыркылау, камчы белән яру, суктыру; 2. *перен.* фаш итү; каты тәнкыйть итү.

**БИЧЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. камчылану, камчы белән суктырылу; 2. *перен.* фаш ителү; каты тәнкыйть ителү.

**БИЧЁВКА** *ж.* — к. бечёвка.

**БИШЬ** *частица устар.* — дисең, дисең әле; *как бишь его зовут?* — ничек дисең әле аның исеме? ◇ **То бишь** — ягъни.

**БЛА'ГО** I *ср.* — 1. игелек, яхшылык, бәхет; *стремление к общему благу* — гомуми бәхеткә омтылу; 2. *чаще мн.* байлыклар, рәхәтләр, ямьнәр; *блага жизни* — тормыш рәхәтләре (ямьнәре); *материальные блага* — материаль байлыклар. ◇ **Всех благ** — хәерле юл, сау бул. **Ни за какие блага в мире** — һич тә, һичбер очракта да. **Благо, что...** — ярый әле...

**БЛА'ГО** II *союз, разг.* — ... -ганлыктан, ... -ганга күрә; *быстро закончим уборку урожая, благо тракторами и машинами мы обеспечены* — тракторлар һәм машиналар белән тәэмин ителгән булганлыктан, без урып-җыюны тиз төгәлләячәкбез.

**БЛАГОВЕ'РНЫЙ** *в знач. сущ. шутл.* — хәләл җефет, турылыклы (ир, хатын).

**БЛА'ГОВЕСТ** *м. церк.* — чиркәү кагу (гыйбадәт башлануын белдерү өчен).

**БЛА'ГОВЕСТИТЬ** *несов.* — 1. чиркәүгә чакыру (чиркәү кагып; мөселманнардагы азан әйтүгә туры килә); 2. *перен.* дөньяга җәю, тарату (хәбәрне).

**БЛАГОВИ'ДНЫЙ** — күркәм, яраклы. ◇ **Благовидный предлог** — җайлы сәбәп, унайлы сылтау.

**БЛАГОВОЛИ'ТЬ** *несов.* — яхшы мөнәсәбәттә булу, илтифат күрсәтү, яхшы теләктә булу. ◇ **Благоволите ответить** — рәхим итеп җавап бирегез әле.

**БЛАГОВО'НИЕ** *ж.* — 1. хуш ис; 2. *только мн.* хуш исле әйберләр.

**БЛАГОВО'ННИК** *м. бот.* — җир рәйханы.

**БЛАГОВО'ННЫЙ** — хуш исле.

**БЛАГОВОСПИ'ТАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — әдәплелек, тәрбиялелек.

**БЛАГОВОСПИ'ТАННЫЙ** — тәрбияле, әдәпле.

**БЛАГОВРЕ'МЕННЫЙ** *устар.* — үз вакытында эшләнгән.

**БЛАГОГЛУ'ПОСТЬ** *ж. ирон.* — житди (кыяфәт белән эшләнгән) ахмаклык.

**БЛАГОГОВЕ'ЙНО** *нареч.* — түбәнчелек белән, хөрмәтләп, ихтирам белән.

**БЛАГОГОВЕ'ЙНЫЙ** — түбәнчелекле, олылаучан, хөрмәтләүчән.

**БЛАГОГОВЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — тирән хөрмәт, зур түбәнчелек, олылау.

**БЛАГОГОВЕ'ТЬ** *несов.* — олылау, хөрмәтләү, тирән хөрмәт күрсәтү.

**БЛАГОДАРИ'ТЬ** *несов.* — рәхмәт әйтү, рәхмәт белдерү; *благодарю вас* — рәхмәт сезгә.

**БЛАГОДА'РНО** *нареч.* — рәхмәт белдереп.

**БЛАГОДА'РНОСТЬ** *ж.* — 1. рәхмәт; благодарность (хәрби); 2. *разг.* взятка. ◇ **В знак благодарности** — рәхмәт йөзеннән. **Рассыпаться в благодарностях** — рәхмәтләр уку.

**БЛАГОДА'РНЫЙ** — 1. яхшылыкның кадерен белүче, яхшылыкка яхшылык белән җавап бирүче; 2. нәтиҗәле, уңышлы; *благодарный труд* — нәтиҗәле хезмәт.

**БЛАГОДА'РСТВЕННЫЙ** — рәхмәт... -ы; *благодарственное письмо* — рәхмәт хаты.

**БЛАГОДАРЯ'** *предлог с дат. п.* — ... аркасында, ... -га күрә, ... сәбәпле, ... -лыктан; *он спасся только благодаря присутствию духа* — ул каушап калмау аркасында гына котылды.

**БЛАГОДА'ТНЫЙ** — рәхәт, ямьле, иркен; бай, мул; файдалы; *благодатный край* — бай ил; *благодатный дождь* — файдалы яңгыр; *благодатный вечер* — рәхәт кич.

**БЛАГОДА'ТЬ** *ж. мн.* нет — рәхәт; *какая тут благодать!* — нинди рәхәт монда!

**БЛАГОДЕ'НСТВЕННЫЙ** — бәхетле, тыныч, шат.

**БЛАГОДЕ'НСТВИЕ** *ср. мн.* нет — тынычлык, рәхәт тормыш, иркен тормыш, иминлек, имин тормыш.

**БЛАГОДЕ'НСТВОВАТЬ** *несов. устар.* — рәхәт яшәү, муллыкта яшәү, иркен яшәү, бәхетле яшәү, иминлектә яшәү.

**БЛАГОДЕ'ТЕЛЬ** *м.*, **БЛАГОДЕ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — игелек күрсәтүче, яхшылык итүче, кешегә ярдәм итүче, яклаучы, шәфкать күрсәтүче.

**БЛАГОДЕ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — к. благодетельный 1.

**БЛАГОДЕ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. файдалылык, файдалы булу, шифалылык, шифалы булу; 2. игелеклелек, ярдәмчел булу.

**БЛАГОДЕ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. файдалы, шифалы; *благодетельное влияние климата* — климатның файдалы тәэсире; 2. *устар.* игелекле, ярдәмчел.

**БЛАГОДЕ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов.* — яхшылык итү, яклау, игелек күрсәтү.

**БЛАГОДЕЯ'НИЕ** *ср.* — яхшылык, игелек.

**БЛАГОДУ'ШЕСТВОВАТЬ** *несов.* — кайгысыз яшәү, тыныч яшәү.

**БЛАГОДУ'ШИЕ** *ср. мн.* нет — 1. ягымлылык, йомшак күңеллелек; 2. *неодобр.* гамьсез караш.

**БЛАГОДУ'ШНО** *нареч.* — 1. ягымлылык белән, йомшак күңел белән, яхшылык теләп, ягымлылык күрсәтеп; 2. *неодобр.* салкын, гамьсез.

**БЛАГОДУ'ШНЫЙ** — 1. ягымлы, йомшак күңелле; 2. *неодобр.* гамьсез.

**БЛАГОЖЕЛА'ТЕЛЬ** *м.*, **БЛАГОЖЕЛА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — яхшылык теләүче.

**БЛАГОЖЕЛА'ТЕЛЬНО** *нареч.* — яхшылык теләп, дусларча, киң күңел белән.

**БЛАГОЖЕЛА'ТЕЛЬНЫЙ** — яхшылыклы, уңыш теләүчел, дусларча..., киң күңел белән...; *благожелательный приём* — дусларча каршы алу.

**БЛАГОЖЕЛА'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов.* — яхшылык теләү, уңыш теләү.

**БЛАГОЗВУ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет — аһәнлелек.

**БЛАГОЗВУ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. благозвучие.

**БЛАГОЗВУ'ЧНЫЙ** — аһәнле.

**БЛАГО'Й** I *устар.* — яхшы.

**БЛАГО'Й** II *обл.* — 1. дуамал, тинтәк; 2. ямьсез, начар, күңелсез. ◇ **Благим матом** — ачы тавыш белән, акырып.

**БЛАГОЛЕ'ПИЕ** *ср. мн.* нет, *устар.* — мәһабәтлек, күркәмлек, матурлык.

**БЛАГОМЫ'СЛЯЩИЙ** *устар.* — 1. яхшы фикерле, яхшы ниятле; 2. акыллы, саф фикерле.

**БЛАГОНАДЁЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(преданность)* ышанычлылык, турылыклылык; 2. *устар.* өметлелек, төплелек.

**БЛАГОНАДЁЖНЫЙ** — 1. *(преданный)* ышанычлы; турылыклы; 2. *устар.* өметле, төпле.

**БЛАГОНАМЕ'РЕННЫЙ** — 1. *дореврл.* революциягә каршы, монархия яклы; 2. *устар.* намуслы, турылыклы.

**БЛАГОНРА'ВИЕ** *ср. мн.* нет, *устар. ирон.* — әдәплелек, тәрбиялелек, әхлаклылык.

**БЛАГОНРА'ВНЫЙ** *устар.* — әдәпле, тәрбияле, әхлаклы, күркәм холыклы.

**БЛАГООБРА'ЗИЕ** *ср. мн.* нет — күркәм кыяфәтлелек, матур кыяфәтлелек, сөйкемлелек.

**БЛАГООБРА'ЗНЫЙ** — күркәм кыяфәтле, матур кыяфәтле, сөйкемле.

**БЛАГОПОЛУ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(спокойная жизнь)* иминлек, тынычлык; 2. *(обеспеченность)* иркенлек, муллык.

**БЛАГОПОЛУ'ЧНО** *нареч.* — 1. сау-сәламәт, хәвеф-хәтәрсез, бәла-казасыз, тыныч кына; 2. шома; *внешне всё будто обстоит благополучно* — тыштан караганда бөтенесе дә шома бара шикелле.

**БЛАГОПОЛУ'ЧНЫЙ** — 1. уңышлы; *благополучный ход дела* — эшнең уңышлы барышы; 2. имин; *район, благополучный в отношении инфекции* — инфекциядән имин район.

**БЛАГОПРИОБРЕТЁННЫЙ** — 1. үзе тырышып тапкан (ата-бабадан калмаган); 2. *перен.* нәселдән күчмәгән, нәселдән килмәгән.

**БЛАГОПРИСТО'ЙНЫЙ** — 1. әдәпле, әхлаклы, инсафлы, тыйнак; 2. *устар.* яраклы, уңайлы, лаеклы.

**БЛАГОПРИЯ'ТНО** *нареч.* — уңайлы, жайлы, файдалы.

**БЛАГОПРИЯ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. уңайлылык, файдалылык; 2. *устар.* к. благосклонность.

**БЛАГОПРИЯ'ТНЫЙ** — 1. уңайлы, җайлы; *благоприятные обстоятельства* — уңайлы шартлар; 2. яхшы, мактаулы, күңелле; *благоприятная рецензия* — мактаулы рецензия; *благоприятные вести* — күңелле хәбәрләр.

**БЛАГОПРИЯ'ТСТВОВАТЬ** *несов.* — уңай шартлар тудыру, булышлык итү, ярдәм итү.

**БЛАГОРАЗУ'МИЕ** *ср. мн.* нет — акыллылык; саклык.

**БЛАГОРАЗУ'МНЫЙ** — акыллы, сак; акылга ятышлы, акылга сыешлы.

**БЛАГОРАСПОЛОЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. благосклонность.

**БЛАГОРАСПОЛО'ЖЕННЫЙ** — к. благосклонный.

**БЛАГОРО'ДНО** *нареч.* — яхшы, намус белән.

**БЛАГОРО'ДНЫЙ** — 1. намуслы, вөҗданлы, турылыклы, мәрхәмәтле; *благородный человек* — намуслы, турылыклы кеше; 2. гүзәл, яхшы; *благородный поступок* — гүзәл эш. 3. *устар.* дворян, аристократ нәселеннән. ◇ **Благородные металлы** — затлы металлар (алтын, көмеш, платина). **Риск — благородное дело** — ятып калганчы атып кал; таяк баш ярыр, тәвәккәл таш ярыр.

**БЛАГОРО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — намуслылык, турылыклылык, яхшылык; вөҗданлылык, риясызлык.

**БЛАГОСКЛО'ННО** *нареч.* — илтифат белән, түбәнчелек белән, мәрхәмәт белән.

**БЛАГОСКЛО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — ягымлылык, мәрхәмәтлелек, яхшы мөнәсәбәт, түбәнчелек, илтифатлылык; *проявить к кому-н. благосклонность* — кемгә дә булса ягымлылык күрсәтү, кемгә дә булса яхшы мөнәсәбәттә булу.

**БЛАГОСКЛО'ННЫЙ** — ягымлы, түбәнчелекле, игелекле, мәрхәмәтле, илтифатлы.

**БЛАГОСЛОВЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *рел.* дога, фатиха; 2. *(напутствие)* яхшы теләк; 3. *(разрешение)* ризалык.

**БЛАГОСЛОВЕ'ННЫЙ** — бәхетле, шат, рәхәт.

**БЛАГОСЛОВИ'ТЬ** *сов.* — 1. *рел.* фатиха бирү, ризалык бирү; 2. *(напутствовать)* яхшы теләк теләү; 3. *(разрешить)* ризалык бирү; 4. *(возблагодарить)* шөкер итү; 5. *(одобрить)* хуплау, яхшы дип тану.

**БЛАГОСЛОВИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. благословляться.

**БЛАГОСЛОВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. благословить.

**БЛАГОСЛОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *рел.* догасын алу, фатихасын алу; 2. *(получать напутствие)* яхшы теләк алу; 3. *(получать разрешение)* ризалыгын алу.

**БЛАГОСОСТОЯ'НИЕ** *ср. мн.* нет — иркен тормыш, мул тормыш, иркенлек, муллык, байлык.

**БЛА'ГОСТНЫЙ** *устар.* — мәрхәмәтле, мәрхәмәтчел, яхшылыклы, тыныч.

**БЛАГОСТЫ'НЯ** *ж. устар.*—1. мәрхәмәт, шәфкать; юмартлык; 2. сәдака, хәер.

**БЛА'ГОСТЬ** *ж. мн.* нет — яхшылык, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек, йомшак күңеллелек.

**БЛАГОТВОРИ'ТЕЛЬНОЕ О'БЩЕСТВО** *доревол.*— җәмгыяте хәйрия.

**БЛАГОТВОРИ'ТЕЛЬ** *м.*, **БЛАГОТВОРИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. устар.* — хәер-сәдака бирүче (ярлыларга аз-маз материаль ярдәм күрсәткән булып, үзенең эксплуататорлык йөзен яшерүче).

**БЛАГОТВОРИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ярлыларга материаль ярдәм (буржуаз җәмгыятьтә буржуазиянең, ярлыларга ярдәм күрсәтәм дигән булып, үзенең эксплуататорлык табигатен яшерү чарасы).

**БЛАГОТВОРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — материаль ярдәм күрсәтү ... -ы; *благотворительный комитет* — материаль ярдәм күрсәтү комитеты.

**БЛАГОТВОРИ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов. устар.* — материаль ярдәм күрсәтү.

**БЛАГОТВОРИ'ТЬ** *несов.* — к. благотворительствовать.

**БЛАГОТВО'РНЫЙ** — шифалы, файдалы.

**БЛАГОУСМОТРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *устар.*: **полагаться на чьё-либо благоусмотрение**— кемнең дә булса хөкеменә таяну; **предоставлять на чьё-либо благоусмотрение**—кемнең дә булса карамагына тапшыру.

**БЛАГОУСТРО'ЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — төзеклек, җыйнаклык, житешлелек, уңайлылык.

**БЛАГОУСТРО'ЕННЫЙ** — төзек, җыйнак, житешле, уңайлы; *благоустроенный город* — төзек шәһәр.

**БЛАГОУСТРО'ЙСТВО** *ср. мн.* нет — төзекләндерү, төзеклек.

**БЛАГОУХА'НИЕ** *ср.* — хуш ис.

**БЛАГОУХА'ННЫЙ** *устар.* — хуш исле.

**БЛАГОУХА'ТЬ** *несов.* — хуш ис аңкыту, аңкып тору, хуш ис чыгару.

**БЛАГОЧЕСТИ'ВЫЙ** *рел.* — диндар, динчел, тәкъва.

**БЛАГОЧЕ'СТИЕ** *ср. мн.* нет — диндарлык, тәкъвалык.

**БЛАЖЕ'ННО** *нареч.* — шатланып, рәхәтләнеп.

**БЛАЖЕ'ННЫЙ** — 1. бәхетле, шатлыклы, шат күңелле; 2. *простореч.* акылга сайрак, юләрсыман; 3. *церк.* изге. ◇ **Блаженной памяти** — мәрхүм; авыр туфрагы җиңел булсын.

**БЛАЖЕ'НСТВО** *ср.* — рәхәтлек, хозурлык.

**БЛАЖЕ'НСТВОВАТЬ** *несов.* —рәхәтләнү, хозурлану, кәефләнү, рәхәт яшәү.

**БЛАЖИ'ТЬ** *несов. разг.* — үз сүзләнү, киреләнү.

**БЛАЖНО'Й** *простореч. презрит.* — тинтәк, дивана, кире беткән.

**БЛАЖЬ** *ж. мн.* нет — тинтәклек, юләрлек, диваналык, кирелек.

**БЛА'НЖЕВЫЙ** *устар.* — тән төсле.

**БЛА'НК** *м.* — бланк (тутырып язу өчен буш урыннар калдырып басылган кәгазь).

**БЛА'НКОВЫЙ** — бланк... -ы; бланклар...-ы; *бланковая книжка* — бланклар кенәгәсе.

**БЛАСТО'МА** *ж. мед.* — бластома, шеш.

**БЛАТ** *м. мн.* нет — блат (1. җинаять, караклык; 2. караклар теле, жаргоны). ◇ **По блату** *простореч. вульг.* — блат белән, законсыз юл белән.

**БЛАТНО'Й, БЛА'ТНЫЙ** — караклар ... -ы, җинаятьчеләр ... -ы; *блатной жаргон* — караклар (җинаятьчеләр) жаргоны.

**БЛЕВА'ТЬ** *несов. вульг.* — косу.

**БЛЕВО'ТИНА** *ж. мн.* нет, *простореч.*— 1. косык; 2. *перен. разг. вульг.* хәшәрәт, кабахәт, җирәнгеч.

**БЛЕДНЕ'ТЬ** *несов.* — 1. *(становиться бледным)* төс китү, агарыну, чырай китү; 2. *перен.* әһәмиятсез булып калу, әһәмиятен югалту. ◇ **Бледнеет небосклон** — күк йөзе тоныклана (тоныклана бара). **Бледнеет закат** — шәфәкъ сүнә (сүнә бара).

**БЛЕ'ДНО** *нареч.*— аксыл, тонык, томанлы; көчсез.

**БЛЕДНОЛИ'ЦЫЙ** — агарынган йөзле, ак чырайлы.

**БЛЕ'ДНОСТЬ, БЛЕДНОТА'** *ж. мн.* нет — агарынганлык, чырайсызлык.

**БЛЕ'ДНЫЙ** — 1. төссез, төсе киткән, агарынган, чырайсыз, нурсыз; 2. *перен.* тонык, томсык; *бледное небо* — тонык (томсык) күк; 3. *перен.* көчсез, сыек; *бледный рассказ* — көчсез хикәя, сыек хикәя.

**БЛЁКЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — шиңгәнлек, сулганлык, уңганлык.

**БЛЁКЛЫЙ** — шиңгән, сулган, уңган; *блёклый цветок* — шиңгән чәчәк.

**БЛЁКНУТЬ** *несов.* — 1. шиңү, сулу, уңу; тоныклану; *цветы блёкнут* — чәчәкләр шиңәләр; *блёкнет взор* — караш тоныклана; *краска блёкнет* — буяу уңа; 2. *перен.* сүнү, сүнә бару; *мысли о ней вяло блёкли* — аның турындагы уйлар акрынлап сүнә баралар иде.

**БЛЕСК** *м. мн.* нет — 1. ялтырау; *блеск солнца* — кояш ялтыравы; 2. *перен. (пышность, великолепие)* зиннәтлелек, матурлык, мәһабәтлек; 3. дан; *я дворянскому нашему роду блеска лирой моей не стяжал* (Некрасов) — мин үзебезнең дворян халкына шигырьләрем белән дан китермәдем. ◇ **Блеск ума** — акыл үткенлеге, зирәклек. **Блеск слова** — сүзнең җанлылыгы, матурлыгы. **Блеск таланта** — талантның көчлелеге, зурлыгы.

**БЛЕСНА'** *ж.* — блесна, ялтыравык, алдавыч (ялтыравыклы металлдан балыкка охшатып ясалган алдавыч).

**БЛЕСНУ'ТЬ** *сов.* — 1. ялтырап китү; *блеснула молния* — яшен ялтырап китте; 2. *перен.* таңга калдыру; *пианистка блеснула своей техникой* — пианистка үзенең техникасы белән таңга калдырды; 3. *перен.* кылт итеп искә төшү, ялтырап китү; *у меня блеснула мысль* — бер фикер кылт итеп исемә килеп төште; *блеснула надежда* — өмет чаткысы ялтырап китте. ◇ **Блеснула улыбка на лице** — елмаеп куйды.

**БЛЕСТЕ'ТЬ** *несов.* 1. ялтырау, ялтырап тору, җемелдәү, җемелдәп тору; җем-җем итү, ялкылдау, ялкылдап тору; 2. *перен.* ис китәрү, танга калдыру, шаккатыру; *музыкант блещет своим талантом* — музыкант үзенең таланты белән ис китәрә.

**БЛЁСТКИ** *мн.* — 1. (*для украшения*) ялтыравыклы зиннәт әйберләре; 2. *перен.* ялтыравыклар (мәсәлән, су өстендә кояш нурлары чагылудан күренә торган); 3. чаткылар; *блёстки остроумия* — үткен фикерлелек чаткылары, акыл чаткылары.

**БЛЕСТЯ'ЩЕ** *нареч.* — менә дигән итеп, шәп, бик яхшы.

**БЛЕСТЯ'ЩИЙ** — 1. ялтыравыклы, ялтырый торган, ялтырап торган; 2. *перен.* бик шәп, бик яхшы, менә дигән; гүзәл; *он произнёс блестящую речь* — ул бик шәп (менә дигән) речь сөйләде; *блестящие победы Советской Армии* — Совет Армиясенең гүзәл җиңүләре.

**БЛЕФ** *м.* — уйдырма, коры куык; *угрозы наших противников оказались блефом* — безнең дошманнарның куркытулары коры куык кына булып чыкты.

**БЛЕФОВА'ТЬ** *несов.* — юри куркыту.

**БЛЕЯ'ТЬ** *несов.* — мәэлдәү, кычкыру (сарык, кәҗә турында).

**БЛИЖА'ЙШИЙ** — 1. (*по расстоянию*) иң якын, иң якындагы; 2. (*по времени*) чираттагы. ◇ **При ближайшем участии...** — ...ның якыннан катнашуы белән.

**БЛИ'ЖЕ** — якынрак. ◇ **Ближе к делу** — кыскарак тот, мәсьәләгә якынрак кил.

**БЛИ'ЖНИЙ** — 1. якын, якындагы, якын җирдәге; *Ближний Восток* — Якын Көнчыгыш; 2. *в знач. сущ. церк. книж.* дин кардәше.

**БЛИЗ** *предлог* — ... якынында, ... тирәсендә; *близ станции* — станция тирәсендә.

**БЛИЗЁХОНЬКО** *нареч.* — бик якын, яп-якын, якын гына.

**БЛИ'ЗИТЬСЯ** *несов.* — якынлашу, якынаю, якынлашып килү, якын килү; *близится осень* — көз якынлаша, якынлашып килә.

**БЛИ'ЗКИЕ** — якыннар, якын туганнар, якын дуслар.

**БЛИ'ЗКИЙ** — якын; *близкое расстояние* — якын ара; *близкий друг* — якын дус; *близкий родственник* — якын кардәш.

**БЛИ'ЗКО** *нареч.* — 1. якын, якында; *близко жить* — якын тору; 2. якыннан, яхшы; *близко познакомиться* — якыннан танышу.

**БЛИЗЛЕЖА'ЩИЙ** — якындагы; *близлежащая деревня* — якындагы авыл.

**БЛИЗНЕЦЫ'** *мн.* (*ед. близнец*) — игезәкләр, игез балалар.

**БЛИЗОРУ'КИЙ** — 1. (*имеющий плохое зрение*) күрә карауч ы (еракт ан начар күрүче). 2. *перен.* (*недальновидный*) сукыр, алдан күрә алмаучы; *близорукая политика* — сукыр политика.

**БЛИЗОРУ'КОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. күрә карау, ерактан күрмәү; 2. *перен.* сукырлык, алдан күрә алмаучылык; *политическая близорукость* — политик сукырлык.

**БЛИ'ЗОСТЬ** *ж.* — 1. якынлык; *близость взглядов* — карашларның якынлыгы; 2. дуслык мөнәсәбәтләре; *между ними установилась близость* — алар арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнашты.

**БЛИК** *м.* — ак тап, ак тимгел, якты шәүлә (кара фонга төшкән ак тап, якты шәүлә).

**БЛИН** *м.* — белен. ◇ **Как блины печёт** — кулы кулга иярми, бик тиз эшли. **Первый блин комом** — беренче коймак төерле була.

**БЛИНДА'Ж** *м. воен.* — блиндаж (снарядлардан саклану өчен ясалган корылма).

**БЛИ'ННЫЙ** — белен... -ы; *блинная сковорода* — белен табасы.

**БЛИСТА'ТЕЛЬНЫЙ** — шанлы, шөһрәтле, данлыклы, күренекле, шәп, гүзәл.

**БЛИСТА'ТЬ** *несов.* — к. блестеть. ◇ **Блистать отсутствием** — юклыгы сизелеп тору.

**БЛОК I** *м. тех.* — блок, чыгыр; *поднимать блоком* — чыгыр белән күтәрү.

**БЛОК II** *м. полит.* — блок (берничә дәүләтнең, партиянең, оешманың бергәләп эш итү максаты белән берләшүләре); *блок коммунистов и беспартийных* — коммунистлар һәм партиясезләр блогы.

**БЛОКА'ДА** *ж. мн.* нет — блокада, камау, камап тоту (берәр дәүләтне яки аның бер өлешен, аерым таләпләрне үтәүгә мәҗбүр итү өчен, хәрби, политик яки экономик яктан изоляцияләү, камап тору).

**БЛОКА'ДНЫЙ** — блокада... -ы, блокадалау... -ы; *блокадные суда* — блокада (блокадалау) корабльләре.

**БЛОКИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. *воен.* блокада ясау, камап тору; 2. *ж.-д.* юлны ябу (тимер юлда); 3. *перен.* киртә булу.

**БЛОКИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. политик блокка керү; 2. *страд.* камалу, камап алыну, блокада ясалу.

**БЛОКНО'Т** *м.* — блокнот, кесә дәфтәре, кесә дәфтәре.

**БЛОНДИ'Н** *м.* — блондин (аксыл сары чәчле һәм ак йөзле ир кеше).

**БЛОНДИ'НКА** *ж.* — блондинка (аксыл сары чәчле, ак йөзле хатын-кыз).

**БЛОНДИ'НИСТЫЙ** — аксыл сары чәчле.

**БЛОХА'** *ж.* — борча.

**БЛО'ЧНЫЙ** — 1. чыгыр... -ы; *блочная верёвка* — чыгыр бавы; 2. чыгырлы; *блочная лампа* — чыгырлы лампа.

**БЛОШИ'НЫЙ** — борча... -ы; *блошиный укус* — борча тешләве.

**БЛОШИ'СТЫЙ, БЛОШЛИ'ВЫЙ** — борчалы, борчаланган; *блошливая собака* — борчалы эт.

**БЛО'ШКА** *ж.* — 1. к. блоха; 2. *только мн.* сикерчәкләр (йомшак әйбер өстенә куеп кысканда сикерә торган сөяк түгәрәкләр, уенчыклар).

**БЛО'ШНИЦА** *ж. бот.* — борча үләне.

**БЛУД** *м. мн.* нет, *устар.* — уйнаш, зина, фәхеш, азгынлык.

**БЛУДИ'ТЬ I** *несов.* — 1. *неодобр.* уйнашлык итү, азып йөрү; 2. *простореч.* шаяру, шуклану.

**БЛУДИ'ТЬ** II *несов.* — адашып йөрү.

**БЛУДЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(распутство)* азгынлык; 2. *(шаловливость)* шуклык, шаянлык.

**БЛУДЛИ'ВЫЙ** — 1. азгын; 2. *простореч.* шук, шаян.

**БЛУ'ДНИ** *мн. разг.* — уйнашлык мәҗаралары, азып йөрүләр.

**БЛУ'ДНИК** *м.* — азгын, азган-тузган.

**БЛУДНИ'ЦА** *ж.* — 1. азгын, азган-тузган; 2. фахишә.

**БЛУ'ДНЫЙ** — азгын, уйнашчылыкка бирелгән. ◇ **Блудный сын** — 1. *устар.* юлдан язган ул (ата-анасын санга санамыйча, туган өен ташлап китеп, соңыннан кире кайткан ул); 2. *перен.* бераэ коллективта аның таләпләренә буйсынмаучы кеше.

**БЛУДЯ'ЩИЙ** — 1. уйнашлык итүче; 2. адашып йөрүче.

**БЛУЖДА'ТЬ** *несов.* — 1. адашып йөрү; 2. *(странствовать)* ил гизү, дөнья гизү. ◇ **Мысли блуждают** — зиһене таралган.

**БЛУЖДА'ЮЩИЙ** — адашып йөрүче, адашып йөри торган. ◇ **Блуждающий огонёк, блуждающие огни** — убыр уты (сазлыкларда, каберлекләрдә чери торган әйберләрдән чыгып үзеннән-үзе яна торган газ). **Блуждающие звёзды** — сәйяр йолдызлар, гизүче йолдызлар.

**БЛУ'ЗА** *ж.* — блуза (тышкы киң күлмәк).

**БЛУ'ЗКА** *ж.* — блузка (җиңел материядән тегелгән хатын-кыз кофтасы).

**БЛЮ'ДО** *ср.* — 1. *(посуда)* коштабак; 2. *(кушание)* блюдо; *что дали на первое блюдо?* — беренче блюдога нәрсә бирделәр? 3. *(кушание вообще)* аш; *вкусное блюдо* — тәмле аш.

**БЛЮДОЛИ'З** *м. устар.* — тәлинкә ялаучы, әрәм тамак.

**БЛЮ'ДЦЕ** *ср.* — чынаяк тәлинкәсе.

**БЛЮСТИ'** *несов. устар.* — 1. саклау; *блюсти порядок* — тәртип саклау; 2. күзәтү, күзәтеп тору; *блюсти законы* — законнарның үтәлешен күзәтеп тору.

**БЛЮСТИ'СЬ** *несов. устар.* — 1. саклану; 2. *страд.* сакланылу, күзәтелү.

**БЛЮСТИ'ТЕЛЬ** *м.*, **БЛЮСТИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. устар.* — күзәтүче, саклаучы. ◇ **Блюститель порядка** *дореволюц. ирон.* — полицейский.

**БЛЯ'ХА** *ж.* — 1. *(у носильщиков и др.)* бляха, калай; 2. сбруй җизе.

**БОБ** *м.* — 1. *(стручёк)* кузак; 2. *(зерно)* борчак, фасоль; 3. *только мн. (растение)* кузаклы үсемлекләр. ◇ **Бобы разводить** — сафсата сату. **Остаться на бобах** — коры калу, алдану, төпсез чуманга утыру.

**БОБЁР** *м.* — 1. *только ед.* кондыз мехы; 2. *только мн.* кондыз яка, кондыз кием.

**БОБО'** *нареч., детск.* — авырта (балалар телендә).

**БОБОВИ'ДНЫЙ** — борчаксыман, фасольсыман.

**БОБО'ВНИК** *м.* — 1. ногыт сабагы; 2. кыргый персик.

**БОБО'ВЫЙ** *бот.* 1. — борчак... -ы; фасоль...-ы; *бобовый стручёк* — борчак (фасоль) кузагы; 2. кузаклы; *бобовые растения* — кузаклы үсемлекләр.

**БОБО'К** *м.* — борчак бөртеге, фасоль бөртеге.

**БОБР** *м. зоол.* — кондыз. ◇ **Убить бобра** *ирон.* — алдану, яхшы урынына начарны алу.

**БОБРЁНОК** *м. (мн.* бобрята) *зоол.* — кондыз баласы.

**БО'БРИК** *м.* — бобрик, мәллә, йонлач тула.

**БО'БРИКОМ** *нареч.* — бобриксыман итеп (кыркылган чәч).

**БО'БРИКОВЫЙ** — бобрик...; мәллә...; *бобриковое пальто* — бобрик пальто.

**БОБРО'ВИНА** *ж. мн.* нет — кондыз ите.

**БОБРО'ВЫЙ** — кондыз...; *бобровый воротник* — кондыз яка.

**БОБЫЛИ'ХА** *ж.* — йортсыз-җирсез крестьян хатыны.

**БОБЫ'ЛКА** *ж. обл. простореч.* — йортсыз-җирсез ялгыз крестьян хатын.

**БОБЫ'ЛЬ** *м.* 1. йортсыз-җирсез крестьян; 2. сыеныр урыны булмаган ялгыз кеше.

**БОГ** *м. рел.* — алла, ходай, тәнре. ◇ **Бог знает, бог весть** — алла белсен; билгесез. **Слава богу** — аллага шөкер. **Как бог на душу положит** — ничек җитте алай; үз белдегенчә. **Не дай бог, избави бог, упаси бог** — алла үзе сакласын, була гына күрмәсен. **Бог с ним** — ташла шуны. **На бога надейся, сам не плошай** — атны аллага тапшыр, дилбегәне үзең тот.

**БОГАДЕ'ЛЬНЯ** *ж. дореволюц.* — картлар, инвалидлар йорты.

**БОГА'РНЫЙ** *с.-х.* — сугарылмый торган.

**БОГАТЕ'Й** *м. простореч.* — бай, байгура (ир кеше).

**БОГАТЕ'ЙКА** *ж. простореч.* — бай (хатын-кыз).

**БОГАТЕ'ТЬ** *несов.* — баю.

**БОГА'ТСТВО** *ср.* — байлык, муллык.

**БОГА'ТЫЙ** — 1. бай; *богатый город* — бай шәһәр; *богатая хлебом страна* — икмәккә бай ил; 2. мул; *богатый урожай* — мул уңыш; 3. зур; *богатый опыт* — зур тәҗрибә; 4. бай, гүзәл, зиннәтле; *богатое убранство* — бай җиһаз; 5. *в знач. сущ.* бай (кеше).

**БОГАТЫ'РКА** *ж.* — баһадир, батыр, көчле (хатын-кыз).

**БОГАТЫ'РСКИ, ПО-БОГАТЫ'РСКИ** *нареч.* — батырларча, баһадирларча; батырныкыдай.

**БОГАТЫ'РСКИЙ** — 1. баһадирлар ... -ы; баһадирлар турындагы; *богатырский эпос* — баһадирлар эпосы, баһадирлар турындагы эпос; 2. баһадирлык ... -ы; *блестящие победы, одержанные Советскими войсками в Великой Отечественной войне, показали богатырскую мощь Красной Армии и её высокое воинское мастерство* — Совет гаскәрләренең Бөек Ватан сугышында ирешкән гүзәл җиңүләре Кызыл Армиянең баһадирлык көчен һәм югары хәрби осталыгын күрсәтте. ◇ **Спать богатырским сном** — каты йоклау.

**БОГАТЫ'РСТВО** *ср. мн.* нет — 1. баһадирлык, батырлык; 2. *собир.* баһадирлар.

**БОГАТЫ'РЬ** *м.* — баһадир, пәһлеван, батыр.

**БОГА'Ч** *м.*, **БОГА'ЧКА** *ж.* — бай.

**БОГЕ'МА** *ж. мн.* нет — богема (1. буржуаз җәмгыятьтә — тәэмин ителмәгән, тәртипсез һәм гамьсез тормыш алып бара торган актёрлар, художниклар, әдәбиятчылар һ. б. интеллигентлар; 2. шундый кешеләрнең тәртипсез көнкүреше).

**БОГОБОЯ'ЗНЕННЫЙ** *церк.* — диние, динаятьле, диндар, тәкъва.

**БОГОИСКА'ТЕЛЬ** *м.* — алла эзләүче (тормышның барлык сорауларына диннән җавап эзләүче кеше).

**БОГОИСКА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *истор.* — алла эзләүчелек (XIX йөзнең ахырында һәм XX йөзнең башында Россиядә социаль каршылыкларның чишелешен диннән эзләгән дини-философик агым).

**БОГОМЕ'РЗКИЙ** — 1. *(безбожный)* динсез; 2. *(отвратительный)* җирәнеч, әшәке, нәҗес.

**БОГОМО'Л** *м.* — диндар (гыйбадәтләргә, хаҗга, дини урыннарга йөрүче).

**БОГОМО'ЛЕЦ** *м.*, **БОГОМО'ЛКА** *ж.* — аллага гыйбадәт кылучы.

**БОГОМО'ЛЬЕ** *ср. устар.* — хаҗга бару, дини урыннарга йөрү.

**БОГОМО'ЛЬНЫЙ** — диние, диндар, гыйбадәтчел.

**БОГООТСТУ'ПНИК** *м.*, **БОГООТСТУ'ПНИЦА** *ж.* — мөртәт, диннән язган, динен ташлаган.

**БОГОПРОТИ'ВНЫЙ** — 1. аллага дошман; 2. *перен.* җирәнеч, чиркәнеч.

**БОГОРО'ДИЦА** *ж. церк.* — Гайса анасы (христианнарда); Мәрьям ана (мөселманнарда).

**БОГОРО'ДСКАЯ ТРАВА'** *бот.* — чабыр үләне.

**БОГОСЛО'В** *м.* — 1. дин белгече; 2. *истор.* духовная семинария шәкерте.

**БОГОСЛО'ВИЕ** *ср. мн.* нет — дин өйрәтмәләре, дини тәгълимат.

**БОГОСЛО'ВСКИЙ** — дини; *богословские споры* — дини бәхәсләр.

**БОГОСЛО'ВСТВОВАТЬ** *несов.* — дини мәсьәләләр буенча бәхәсләшү.

**БОГОСЛУЖЕ'БНЫЙ** — дини.

**БОГОСЛУЖЕ'НИЕ** *ср. рел.* — намаз уку, гыйбадәт кылу.

**БОГОСПАСА'ЕМЫЙ** *разг. шутл.* — тыныч яшәүче.

**БОГОСТРОИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *истор.* — алла төзүчелек (1905—07 еллар революциясеннән соң реакция чорында Россиядә социал-демократик интеллигенциянең тотнаксыз элементлары арасында килеп чыккан дини-философик реакцион агым.)

**БОГОТВОРИ'ТЬ** *несов.* — 1. *(обожать)* бик нык ярату, сөю, табыну, алласы кебек күрү; 2. *(обожествлять)* алла дип тану, аллалаштыру.

**БОГОУГО'ДНЫЙ** *устар. церк.* — аллага яраклы. ◇ **Богоугодное заведение** *дорев.* — җәмгыяте хәйрия; картлар, инвалидлар йорты.

**БОГОХУ'ЛЬНЫЙ** — алланы сүгү...-ы; кәфер; *богохульные речи* — алланы сүгү сүзләре, кәфер сүзләр.

**БОГУ'ЛА** *ж. бот.* — тубылгы (агачы).

**БОДА'ТЬ** *несов.* — сөзү (хайваннар турында).

**БОДА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. сөзү (хайваннар турында); 2. сөзешү.

**БОДЛА'Н** *м. бот.* — җиде буын (үсемлек).

**БОДЛИ'ВЫЙ** — сөзгәк.

**БОДНУ'ТЬ** *сов.* — сөзеп җибәрү.

**БОДРИ'ТЬ** *несов.* — дәртләндерү, дәрт кертү, күңел күтәрү, рухландыру. ◇ **Бодрить коня** — атны ярсыту.

**БОДРИ'ТЬСЯ** *несов.* — бирешмәскә тырышу, үзеңне кыю тоту.

**БО'ДРО** *нареч.* — дәрт белән, күтәренке рух белән.

**БО'ДРОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. дәртлелек, күңел күтәренкелек; рухи күтәренкелек; 2. *устар.* кыюлык.

**БО'ДРСТВОВАТЬ** *несов.* — 1. йокламау, уяу булу; 2. *устар.* күзәтү, кайгырту.

**БО'ДРЫЙ** — 1. шат күңелле, таза, нык, егетсыман; *бодрый старик* — таза, нык, егетсыман карт; 2. күтәренке, шатлыклы; *бодрое настроение* — күтәренке, шатлыклы күңел; 3. дәртле, кыю; *бодрый вид* — дәртле кыяфәт.

**БОЕВИ'К** *м.* — боевик (1. *истор.* революцион партиянең сугышчан дружинасы члены (революциягәчә); 2. *кино, разг.* халык бик ярата торган кинофильм).

**БОЕВО'Й** — 1. хәрби; *боевой приказ* — хәрби приказ; *боевая тревога* — хәрби тревога; 2. *полит.* сугышчан; *боевая организация* — сугышчан оешма; 3. *перен.* булдыклы, үткен; *боевой парень* — булдыклы егет; 4. *перен.* кыю, күтәренке, дәртле; *боевое настроение* — күтәренке рух; 5. *перен.* көнүзәк, бик кирәкле, көн үзәгендәге (шушы көн өчен әһәмиятле); *боевая литература* — көнүзәк әдәбият. ◇ **Боевое крещение** — 1. беренче тапкыр сугышка керү; 2. *перен.* чиркәнчек алу (яңа эшне беренче тапкыр яхшы үтәп чыгу). **Боевой клич, боевой призыв** — көрәшкә өндәү. **Боевая готовность** — сугышка хәзерлек.

**БОЁК** *м.* — 1. *(у ружья)* боёк, бәргеч; 2. *(в игре в бабки)* сага, аткый, атабай; 3. *(у цепа)* тәпәч; 4. *(у парового молота)* боёк.

**БОЕПИТА'НИЕ** *ср. только ед.* — сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин итү.

**БОЕПРИПА'СЫ** *мн.* — сугыш припаслары, сугыш кирәк-яраклары (снаряд, патрон, мина һ. б.).

**БОЕСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет — сугышка яраклылык, сугыш сәләте.

**БОЕСПОСО'БНЫЙ** — сугышка яраклы, сугышка сәләтле.

**БОЕ'Ц** *м.* — 1. *(воин)* сугышчы, солдат, гаскәри; 2. *(участник кулачных боёв)* сугышчы, ярышчы, көрәшче; 3. *(на бойне)* сугымчы, чалучы.

**БОЖБА'** *ж. мн.* нет — ант итү, каргану.

**БО'ЖЕ! БО'ЖЕ МОЙ!** *межд.*— 1. я алла, я рабби! *боже мой! что я сделал!* — я алла! ни эшләдем мин! 2. ии! ай-ай! *боже мой, как хорошо!* — ии, нинди яхшы!

**БОЖЕ'СТВЕННО** *нареч. разг.*— искиткеч шәп, гаҗәп матур; *как он божественно пел сегодня!* — ничек ул искиткеч шәп җырлады бүген!

**БОЖЕ'СТВЕННЫЙ —1.** *рел.* илаһи; дини; *божественные книги* — дини китаплар; 2. *(изумительный)* искиткеч шәп, гаҗәп матур, гүзәл, гаҗәеп.

**БОЖЕСТВО'** *ср. рел.*—алла, ходай, тәңре.

**БО'ЖИЙ**—алла...-ы, тәңре...-ы, ходай...-ы; *божий суд* — алла хөкеме (дини). ◇ **Божий человек** — алла бәндәсе, дәрвиш. **Ясно, как божий день** — көн кебек ачык, бик ачык, ап-ачык күренеп тора. **Каждый божий день** — һәр көн, көн саен, тәңренен бирмеш көне. **Явиться на божий свет** — дөньяга килү, анадан туу.

**БОЖИ'ТЬСЯ** *несов.*— каргану, ант итү.

**БОЖО'К** *м.*— 1. *(идол)* кечкенә пот, алла сыны; 2. *перен. (любимец)* барлык кешеләр тарафыннан сөелүче кеше.

**БО'ЖЬЯ КОРО'ВКА** — 1. *зоол.* камка, чуар таракан; 2. *перен.* юаш, басынкы кеше.

**БОЙ** *м.*— 1. ору, сугу; *боем дела не исправишь* — орып-сугып эшне төзәтә алмассың; 2. сую, чалу; *бой скота* — терлек чалу; 3. вату, ватылу; *бой посуды* — савыт-саба вату, савыт-сабаның ватылуы; 4. ватык (пыяла, савыт-саба һ. б.); *в ящике с посудой оказалось много боя* — савыт-саба тутырылган ящикта ватык күп чыкты; 5. сугу; *бой часов* — сәгать сугу; 6. кагу; *барабанный бой* — барабан кагу; 7. ату; *у винтовки хороший бой* — винтовканың атуы яхшы; 8. сугыш; *оборонительный бой* — оборона сугышы; 9. сугышу, көрәшү; *бой быков* — үгезләр сугышы. ◇ **Брать с бою** — 1. (берәр нәрсәне) сугышып алу; 2. көрәшү, зур көч кую аркасында (берәр нәрсәгә) ирешү. **Выпроводить с барабанным боем** — дау куптарып куып чыгару, сөреп чыгару.

**БОЙ-БА'БА** — к. баба.

**БО'ЙКИЙ —** 1. житез, кыю, үткен, булдыклы, тере; *бойкий парень* — җитез егет; 2. тапкыр; *бойкий ум* — тапкыр акыл; 3. халык күп йөри торган, халык кайнап тора торган; *бойкая улица* — халык күп йөри торган урам; 4. кызу; *бойкая торговля* — кызу сәүдә. ◇ **Боек на словах** — теле телгә йокмый, телгә оста. **Бойкое перо** — җинел һәм оста язучы.

**БО'ЙКО** *нареч.* — 1. кыю, елдам; тиз, житез; 2. *(о торговле)* кызу.

**БО'ЙКОСТЬ** *ж. мн.* нет — житезлек, үткенлек, булдыклылык, кыюлык.

**БОЙКО'Т** *м.* — бойкот (1. аерым кеше, оешма яки дәүләт белән мөнәсәбәтне өзү формасында алып барыла торган политик һәм экономик көрәш; 2. системалы рәвештә игътибарсыз калдыру, читкә кагу).

**БОЙКОТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— бойкот ясау, бойкот белдерү, бойкот игълан итү.

**БОЙКОТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— бойкот ясалу, бойкот белдерелү.

**БОЙНИ'ЦА** *ж.* — бойница (1. *воен.* мылтыктан, пулемёттан ату өчен крепость стенасына ясалган ярык, тишек; 2. *устар.* рудникта шартлату эшләре вакытында эшчеләрне саклау өчен ясалган бура).

**БО'ЙНЯ** *ж.* — 1. *(скотобойня)* бойня (терлек сую урыны); 2. *(резня)* кисеш, суеш, үлеш, кан коеш, кырылыш; 3. *(война)* сугыш, канлы сугыш.

**БОЙЦО'ВЫЙ** — сугышуга өйрәтелгән, көрәшүгә өйрәтелгән; *бойцовые петухи* — сугышуга өйрәтелгән әтәчләр.

**БОК** *м.* (*мн.* бока́) — 1. ян, як (гәүдәнең сул яки уң ягы); *у меня болит правый бок* — минем уң ягым авырта; 2. як, кырый (предметның кырые); *изба покосилась на правый бок* — өй уң якка кыйшайган. ◇ **Под боком** — яп-якын, бик якын, якында гына. **Бок о бок** — тезәлеп үк, янәшә. **Взять за бока** — якасыннан тоту (эшкә катнашуга мәҗбүр итү). **По боку** — куеп торыйк, туктатып торыйк; читтә торсын, торып торсын. **Лежать на боку** — тик яту, эшсез яту. **Помять бока** — кыйнап ташлау, кабыргаларын санау. **Переваливаться с боку на бок** — алпан-тилпән йөрү, ава-түнә бару. **Толкнуть в бок** — кабыргага төртү.

**БОКА'Л** *м.*— бокал.

**БОКОВО'Й — 1.** ян; *боковое окно* — ян тәрәзә; 2. кырый; *боковая комната* — кырый бүлмә; 3. яннан искән; *боковой ветер* — яннан искән җил. ◇ **Отправиться на боковую** *разг.*— йокларга яту.

**БО'КОМ** *нареч.* — 1. ян белән, кырын; 2. читләтеп, читтән; *ты не ходи прямо по дороге, а обойди боком* — син туры юлдан барма, читләтеп үт. ◇ **Глядеть боком** — күз чите белән генә карау.

**БОКС** *м. мн.* нет, *спорт.*— бокс (спортның махсус перчаткалар киеп йодрык белән бәрешүдән гыйбарәт булган бер төре).

**БОКСЁР** *м. спорт.*— боксёр (бокс белән шөгыльләнүче, бокс уены остасы).

**БОКСЁРСКИЙ** — боксёр...-ы, боксёрлар ...-ы; *боксёрский приём* — боксёр алымы. ◇ **Боксёрское восстание** *истор.*— боксёрлар восстаниесе (1900 нче елда Кытай крестьяннарының һәм шәһәр ярлыларының чит ил империалистларына һәм үз изүчеләренә каршы баш күтәрүләре).

**БОКСИ'РОВАТЬ** *несов.* — бокс кагыйдәләре буенча сугышу.

**БОЛВА'Н** *м.*— 1. *(чурбан)* түмәр, бүкән; 2. калып (шляпа һ. ш. кебек әйберләрне калыплау өчен); 3. сын, чучело (эченә чүп тутырып ясалган хайван сыны, чучелосы); 4. *перен. бран. (тупица)* ахмак, надан.

**БОЛВА'НКА** *ж.* — 1. *тех.* болванка (металл формаларга коеп тутырылган корыч кисәге; әйбер ясау өчен чүкеч белән тапталган тимер кисәге); 2. *к.* болван 1, 2.

**БОЛГА'РИН** *м.*— болгар.

**БОЛГА'РКА** *ж.*— болгар хатын-кызы.

**БОЛГА'РСКИЙ** — болгар...-ы; *болгарский язык* — болгар теле.

**БОЛГА'РЫ** (балканские) *мн.*— болгарлар, болгар халкы.

**БОЛЕВО'Й** — авырту...-ы; *болевые ощущения* — авырту тойгылары.

**БО'ЛЕЕ** — **1.** к. больше; **2.** ...-рак; *более полные сведения* — тулырак мәгълүматлар. ◇ **Более или менее** — азмы-күпме; *более или менее известно* — азмы-күпме билгеле. **Не более и не менее, как** — нәкъ, нәкъ менә шул; *речь идёт не более и не менее, как о франко-германском соглашении* — сүз нәкъ Франция-Германия килешүе турында бара. **Более чем** — бөтенләй, артык, тәмам, бигрәк тә; *ваше поведение более чем возмутительно* — сезнең үзегезне тотуыгыз бөтенләй (артык) ачу китергеч. **Более того** — алай гына да түгел, аннан да бигрәк; *ваша деятельность бесполезна; более того, она даже вредна* — сезнең эшчәнлегегез файдасыз; алай гына да түгел, ул хәтта зарарлы да. **Всё более и более** — барган саен, торган саен, ... -ганнан ...-а бару; *гул всё более и более утихал* — тавыш тынганнан-тына барды (торган саен тына барды).

**БОЛЕ'ЗНЕННО** *нареч.* — **1.** авыртынып, авырсынып; **2.** *перен.* авыр; *мать болезненно переживает ссоры между детьми* — балалар арасында була торган талашуларны ана авыр кичерә.

**БОЛЕ'ЗНЕННЫЙ** — **1.** чирле, авыру, сырхау, хаста; *болезненное состояние* — авыру хәл; **2.** чирләшкә, чирләүчән, авыручан; *болезненный ребёнок* — чирләшкә бала; **3.** авыру...-ы; *болезненный румянец* — авыру кызыллыгы; **4.** әрнүле; *болезненное ощущение* — әрнүле тойгы; **5.** *перен.* нормаль булмаган; *болезненные явления общественной жизни* — иҗтимагый тормышның нормаль булмаган күренешләре. ◇ **Болезненное самолюбие** — мин-минлек белән авыру, серкәсе су күтәрмәү.

**БОЛЕЗНЕТВО'РНЫЙ** — авыру тудыручы, авыру таратучы; *болезнетворные микробы* — авыру тудыручы микроблар.

**БОЛЕ'ЗНЫЙ** *простореч.* — **1.** *(жалкий)* кызганыч; **2.** *(сострадательный)* шәфкатьле, мәрхәмәтле, кызганучан.

**БОЛЕ'ЗНЬ** *ж.*— **1.** авыру, чир; **2.** *перен.* начарлану, нормадан тайпылу, чыгырыннан чыгу. ◇ **Болезнь повальная** — кизү авыруы.

**БОЛЕ'ЛЬЩИК** *м. спорт.* — болельщик (бер якның җиңүен теләүче).

**БОЛЕ'ТЬ** *несов.* — **1.** авыру, чирләү; *он давно уже болеет* — ул инде күптәннән авырый; **2.** авырту, сызлау; *зубы болят* — тешләрем сызлый; **3.** *перен. устар. (скорбеть)* әрнү, борчылу, ачыну.

**БОЛЕУТОЛЯ'ЮЩИЙ** *мед.* — авыртуны (сызлауны) баса торган, тынычландыра торган.

**БОЛИГОЛО'В** *м. бот.*— түндербаш (агулы үлән).

**БОЛИ'Д** *м. астр.* — болид (бик зур һәм бик якты метеор).

**БОЛОНА'** *ж.* — **1.** оры, агач орысы; агач шеше; **2.** *перен. простореч. обл.* шеш; **3.** төслегән, төчлегән (агачның каеры астындагы иң яшь катлавы).

**БОЛО'НКА** *ж.*— болонка (кечкенә, озын йонлы бүлмә эте).

**БОЛО'ТИНА** *ж. простореч.* — сазлык, сазламык җир.

**БОЛО'ТИСТЫЙ** — сазлы, сазламык; батkak; *болотистая местность* — сазламык җир; *болотистая почва* — сазлы туфрак.

**БОЛО'ТНЫЙ** — саз...-ы; *болотные растения* — саз үсемлекләре.

**БОЛОТНЯ'К** *м.* — саз урманы, саз куаклыгы.

**БОЛО'ТО** *ср.*— саз, сазлык, баткак, баткаклык.

**БОЛТ** *м.*— **1.** болт (ике башы да винтлы яки бер башы винтлы, икенче башы эшләпәле металл стержень); **2.** бикләвеч (ишекне һәм тәрәзә капкачларын бикли торган тимер).

**БО'ЛТАННЫЙ** — болгатылган, тугланган.

**БОЛТА'ТЬ** I *несов.*— **1.** болгату, туглау; *болтать ложкой* — кашык белән болгату; **2.** селкү, селкетү; *болтать ногами* — аякларны селкетү.

**БОЛТА'ТЬ** II *несов.*— **1.** лыгырдау, лыкылдау, юк-барны сөйләү, сафсата сату; такылдау, күп сөйләү; **2.** (аз-маз) сөйләшә белү; *болтать по-французски* — французча аз-маз сөйләшә белү. ◇ **Болтать языком** — юк-барны сөйләү, сафсата сату, чүбек чәйнәү.

**БОЛТА'ТЬСЯ** I *несов.*— **1.** селкенеп тору, тирбәнеп тору (эленгән әйбер турында); *на верёвке болтается бельё* — бауга эленгән кер селкенеп тора; **2.** *перен.* буталып йөрү, эшсез йөрү; *что ты тут болтаешься?* — син ник биредә буталып йөрисең? **3.** *(об одежде)* салынып тору.

**БОЛТА'ТЬСЯ** II *несов. разг. безл.*— сөйләнелү; *болталось тогда много вздору* — ул вакытта күп юк-бар сүзләр сөйләнелгән иде.

**БОЛТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** күп сөйләүчәнлек, бушбугазлык; **2.** сер тотмау.

**БОЛТЛИ'ВЫЙ** — **1.** такылдык, лыгырдык, күп сөйләүчән, бушбугаз; **2.** сер тотмаучан, сер саклый белмәүче, тишек авыз.

**БОЛТНУ'ТЬ** *сов. однокр.*— әйтеп ташлау, ычкындырып ташлау.

**БОЛТОВНЯ'** *ж. мн.* нет — **1.** буш сүз, сүз боткасы, сафсата; **2.** *(непринуждённый разговор)* сөйләшү; **3.** *(сплетни)* гайбәт, уйдырма.

**БОЛТУ'Н** I *м.*, **БОЛТУ'НЬЯ** *ж.* — **1.** күп сөйләүче, такылдык, тел бистәсе; **2.** *(сплетник)* гайбәтче.

**БОЛТУ'Н** II *м.*— чәберчек йомырка, утырган йомырка.

**БОЛТУ'ШКА** *ж.*— **1.** к. болтун I; **2.** *(яичница.)* тәбә; **3.** *(орудие для взбалтывания)*

туглавыч, калак; 4. *(пойло для скота)* болгатма, куе су.

**БОЛТЫХА'ТЬ** *несов. простореч.* — селкетү, тибрәтү.

**БОЛТЫ'ХНУТЬ** *сов. однокр.* — селкетеп кую, тибрәтеп кую.

**БОЛЬ** *ж.* — 1. авырту, сызлау; *головная боль* — баш авырту; 2. *перен.* кайгы, хәсрәт, әрнү, пошыну; *душевная боль* — җан әрнүе (кайгы, хәсрәт).

**БОЛЬНИ'ЦА** *ж.* — больница.

**БОЛЬНИ'ЧНЫЙ** — больница...-ы; *больничная койка* — больница койкасы. ◇ **Больничный листок** — больничный листок (авыруларга бирелә торган кәгазь, бюллетень).

**БО'ЛЬНО** I — 1. *нареч.* авырттырып; *больно ударить* — авырттырып сугу; 2. *в знач. сказ.* авырта, сызлый; *ушам больно* — колакларым авырта; 3. *в знач. сказ. перен.* авыр, күңелсез; *больно переносить такую утрату* — андый югалтуны кичерү авыр.

**БО'ЛЬНО** II *нареч. простореч.* — бик; *больно дешёвый* — бик арзан.

**БОЛЬНО'Й** — 1. авыру, сырхау, хаста, чирле; *больной старик* — авыру карт; 2. *перен.* ватык, ремонт сорый торган; *больные вагоны* — ватык вагоннар. ◇ **Больной вопрос** — авыр мәсьәлә (хәл ителүне сорый торган, ләкин чишелеше кыен булган мәсьәлә).

**БОЛЬША'К** I *м.* — олы юл.

**БОЛЬША'К** II *м. обл.* — семьяда өлкән кеше, семья башлыгы.

**БОЛЬША'Я МЕДВЕ'ДИЦА** *астр.* — Җидегән йолдыз.

**БО'ЛЬШЕ** — 1. *сравн. ст.* зуррак, олырак, күбрәк, артыграк; 2. *нареч.* моннан соң, моннан ары, моннан болай, шуннан соң, артык, бүтән; *чтобы этого больше не было* — моннан ары андый хәл булмасын; *больше я его не видел* — шуннан соң мин аны күрмәдем; *больше не играю* — артык (бүтән) уйнамыйм. ◇ **Больше этого** — алай гына да түгел. **Всё больше и больше** — ...-ганнан...-а барды; *бледнел всё больше и больше* — агарганнан агара барды. **Чем больше..., тем больше...** — никадәр күбрәк..., шулкадәр күбрәк... . **Как можно больше** — мөмкин кадәр күбрәк.

**БОЛЬШЕВИ'ЗМ** *м. мн.* нет — большевизм (ленинизм, ягъни империализм һәм пролетар революцияләр чорының марксизмы, гомумән, пролетар революцияләрнең теориясе һәм тактикасы, аерым алганда, пролетариат диктатурасының теориясе һәм тактикасы).

**БОЛЬШЕВИ'К** *м.* — большевик.

**БОЛЬШЕВИ'СТСКИЙ** — 1. большевиклар...-ы; *большевистская программа* — большевиклар программасы; 2. большевистик; *большевистские темпы* — большевистик темплар; 3. большевикларча...; *большевистское решение трудного вопроса* — кыен мәсьәләне большевикларча чишү.

**БОЛЬШЕВИ'ЧКА** *ж.* — большевичка, большевик хатын-кыз.

**БОЛЬШИ'Е** *в знач. сущ.* — олылар, өлкәннәр, зурлар; *большие ушли, а дети остались дома* — олылар китте, балалар өйдә калды.

**БО'ЛЬШИЙ** — зуррак, зуррагы, олырак, олырагы, күбрәк, күбрәге, артык, артыграк. ◇ **Большею частью, по большей части** — күбесенчә, күпчелектә, башлыча. **Самое большее** — иң күбе, күп дигәндә; *самое большее я пробуду в пути двое суток* — юлда иң күбе ике тәүлек булырмын.

**БОЛЬШИНСТВО'** *ср. мн.* нет — күпчелек; *подавляющее большинство* — иң зур күпчелек.

**БОЛЬШО'Й** — 1. зур; *большая семья* — зур семья; 2. мөһим, әһәмиятле; *большая победа* — әһәмиятле җиңү; 3. олы, дәү; *он уж большой* — ул инде олы; 4. күп; *у него большое знакомство* — аның таныш-белеше күп; *большие деньги* — күп акча. ◇ **Большой палец** — баш бармак. **Большая буква** — баш хәреф. **Большая дорога** — олы юл. **Большой рост** — 1. озын буй; 2. зур үсеш. **Выйти в большой свет** *дорevол.* — аристократлар арасына керү. **Большой плут** — кырыгаллар. **Смотреть большими глазами, делать большие глаза** — шак катып карап тору, ис китеп карап тору.

**БОЛЬШУ'ХА** *ж.* — 1. семьяда иң олы кыз; 2. олы (карт) хатын.

**БОЛЬШУ'ЩИЙ** — бик зур, гаять зур, ифрат зур. ◇ **Большущий привет** — бик күп сәлам.

**БОЛЯ'ЧКА** *ж.* — 1. сызлавык, чуан, шеш, кутыр; 2. *перен.* житешсез як, кимчелекле як; *болячки аппарата* — аппаратның житешсез яклары, кимчелекле яклары.

**БОМ** *межд.* — дан! доң!

**БО'МБА** *ж.* — бомба. ◇ **Влететь бомбой, влететь как бомба** — атылып килеп керү.

**БОМБА'РДА** *ж.* — бомбарда (1. *истор.* XIV—XVI йөзләрдә таш ату өчен кулланылган зур пушка; 2. *мор.* Урта диңгез бассейнында ике мачталы транспорт судносы; 3. *муз.* органда бас трубасы).

**БОМБАРДИ'Р** *м. устар.* — бомбардир (иске заманда артиллериядә хезмәт итүче солдат).

**БОМБАРДИРОВА'ТЬ** *несов.* — 1. тупка тоту, утка тоту, бомбардировать итү; 2. *перен.* йөдәтү, аптырату, яудыру; *бомбардировать друзей письмами* — иптәшләргә хатлар язып йөдәтү, иптәшләргә хатлар яудыру.

**БОМБАРДИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тупка тотылу, утка тотылу, бомбардировать ителү.

**БОМБАРДИРО'ВОЧНЫЙ** — бомбардировка...-ы; *бомбардировочная авиация* — бомбардировка авиациясе.

**БОМБАРДИРО'ВЩИК** *м.* — бомбардировщик (1. бомбардировка самолёты; 2. бомбардировка самолёты лётчигы).

**БОМБИ'ТЬ** *несов.* — бомбага тоту, бомбить итү.

**БОМБОВО'З** *м.* — бомбовоз, бомбардировщик (бомбардировка самолёты).

**БО'МБОВЫЙ** — бомба...-ы; *бомбовые погреба* — бомба базлары.

**БОМБОМЁТ** *м.* — бомбомёт (бомба ата торган корал).

**БОМБОМЁТЧИК** *м.* — бомба ыргытучы.

**БОМБОНЬЕ'РКА** *ж.* — бомбоньерка (конфет салу өчен матур тартма).

**БОМБОУБЕ'ЖИЩЕ** *ср.* — бомбоубежище, бомбадан саклану урыны.

**БОНДА'РИТЬ** *несов.* — мичкә ясау белән шөгыльләнү.

**БОНДАРИ'ХА** *ж. просторeч.* — мичкә ясаучы хатыны.

**БОНДА'РНЫЙ** — мичкә ясау...-ы; *бондарное производство* — мичкә ясау производствосы.

**БОНДА'РНЯ** *ж.* — мичкә ясау мастерское.

**БОНДА'РСКИЙ** — мичкәче...-ы, мичкәчелек...-ы; *бондарское ремесло* — мичкәчелек һөнәре.

**БОНДА'РСТВО** *ср. мн.* нет — мичкәчелек, мичкәчелек һөнәре, мичкә ясау.

**БО'НДА'РЬ** *м.* — мичкәче, мичкә ясаучы.

**БОНИ'СТИКА** *ж.* — бонистика (тарихның кәгазь акчаларны тарихи документ буларак өйрәнә торган ярдәмче бүлеге).

**БОНИТИРО'ВКА** *ж. мн.* нет *с.-х.* — бонитировка, бәя бирү (берәр нәрсәгә сыйфаты ягыннан бәя бирү); *бонитировка почв* — туфракларга бәя бирү; *бонитировка овец* — сарыкларга бәя бирү.

**БО'ННА** *ж. доревол.* — тәрбияче, мөрәббия (буржуаз семьяда яшь балалар тәрбияләүче хатын).

**БОНТО'Н** *м. мн.* нет, *устар.* — нәзакәтлелек, әдәплелек (сүздә һәм мөгамәләдә).

**БОНТО'ННЫЙ** — нәзакәтле, әдәпле, тәкәллефле.

**БО'НУС** *м.* — бонус, премия, бүләк.

**БОР** I *м.* — нарат урманы. ◇ **Откуда сыр бор загорелся** — шуннан ыгы-зыгы килеп чыкты, шуннан эш башланып китте, менә нәрсәдән эш башланып китте. **С бору да с сосенки** или **с бору по сосенке** — аннан-моннан, кырык-корама.

**БОР** II *м. спец.* — бор (теш дәвалау эшендә кулланыла торган корыч борау).

**БОРДО', БОРДО'ВЫЙ** — куе кызыл, чия кызыл.

**БОРДЮ'Р** *м.* — 1. кайма, әдеп; 2. *тип.* бордюр (текстны уратып алган бизәк); 3. бордюр, үсмә киртә (бакчаларда үсеп утырган куе-тыгыз куаклардан ясалган тар гына тәбәнәк киртә).

**БОРЕ'Ц** I *м.* — көрәшче, көрәшүче.

**БОРЕ'Ц** II *м. бот.* — аю көпшәсе, аю табаны.

**БОРЖО'М** *м. мн.* нет — боржом (дәвалану өчен кулланыла торган минераль су).

**БОРЗА'Я, БОРЗО'Й** — бурзай, ау эте.

**БОРЗОПИ'СЕЦ** *м. ирон.* — 1. язучы кешегә, язучы кәмәше (тиз һәм аннан-моннан гына язып ташлаучы автор); 2. *устар.* тиз язучы.

**БО'РЗЫЙ** *устар.* — житез, елгыр, елдам, өлгер, йөгерек, чапкын (гадәттә ат турында).

**БОРЗЯ'ТНИК** *м.* — 1. бурзайлар караучы; 2. бурзайлар белән аулауны яратучы.

**БОРМАШИ'НА** *ж. мед.* — бормашина (тешне кырып тишү машинасы).

**БОРМОТА'ТЬ** *несов.* — мыгырдау.

**БОРМОТУ'Н** *м. разг.* — 1. мыгырдык; 2. Мисыр күгәрчене.

**БОРМОТУ'НЬЯ** *ж.* — к. бормотун 1.

**БО'РОВ** I *м.* (*мн.* боровы) — 1. печтерелгән дуңгыз; 2. *перен.* чиксез юан кеше.

**БО'РОВ** II *м.* (*мн.* борова́) — юллык (мич эчендә төтен юллыгы).

**БОРОВИ'К** *м.* — ак гөмбә, нарат гөмбәсе.

**БОРОВО'Й** — нарат урманлы; *боровое место* — нарат урманлы урын.

**БОРОДА'** *ж.* — 1. сакал; *борода окладистая, борода лопатой* — көрәк сакал; *борода жидкая* — сирәк сакал; 2. зур тәҗрибәле олыгайган кеше. ◇ **Смеяться в бороду** — борын астыннан көлү, мыек астыннан көлү.

**БОРОДА'ВКА** *ж.* — сөял.

**БОРОДА'ВЧАТЫЙ** — сөялле.

**БОРОДА'СТЫЙ** — зур сакаллы, көрәк сакаллы.

**БОРОДА'ТЫЙ** — сакаллы, сакал үстергән.

**БОРОДА'Ч** *м.* — 1. сакалбай, зур сакаллы кеше; 2. *бот.* сакалтамыр.

**БОРОДА'Ч-ЯГНЯ'ТНИК** *зоол.* — бәрәнкарак, бәрән бөркете.

**БОРО'ДКА** *ж.* — 1. кечкенә сакал; 2. *(у ключа)* ачкыч теле (теше), ачкыч балтасы.

**БОРОДО'К** *м.* — тимер тишкеч.

**БОРОЗДА'** *ж.* — 1. буразна; 2. *перен.* *(глубокая морщина)* тирән жыерчык.

**БОРОЗДИ'ЛЬНИК** *м.* — к. бороздник.

**БОРОЗДИ'ТЬ** *несов.* — 1. буразналау, буразна яру, буразна салу; 2. еру, ермалау, ергалау, ермаклау, буразналандырып бетерү; *канавы бороздят поле* — канаулар кырны ергалап бетергән; 3. *перен.* жыерчыклар белән каплау, жыерчыкландыру; *морщины бороздят его лоб* — маңгае жыерчыкланып беткән; аның маңгае жыерчыклар белән капланган; 4. ярып үтү; *пароходы бороздят океаны во всех направлениях* — пароходлар океаннарны барлык юнәлешләрдә ярып үтәләр.

**БОРОЗДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. буразналану, буразналар белән каплану; 2. ермаклану, ергалану; 3. *перен.* жыерчыклар белән каплану.

**БОРОЗДНИ'К** *м.* — буразналагыч, буразна яргыч, китмән.

**БОРО'ЗДЧАТЫЙ** — 1. буразналы, буразналар белән капланган; 2. жыерчыклы.

**БОРОНА'** *ж.* — тырма, җир тырмасы.

**БОРОНИ'ТЬ** *несов.* — 1. тырмалау; 2. *устар. обл.* яклау, саклау.

**БОРОНОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — тырмалау; *боронование поперечно-диагональное* — диагональь-аркылыга тырмалау; *боронование поперечное* — аркылыга тырмалау; *боронование продольно-поперечное* — буйга-аркылыга тырмалау; *боронование продольное* — буйга тырмалау; *боронование фигурное* — фигуралап тырмалау; *бороно-*

*вание челночное* — бер яктан гына тырмалап бару.

**БОРОНОВА'ТЬ** *несов.*— к. боронить 1.

**БОРОНОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— тырмалану.

**БОРОНЬБА'** *ж. мн.* нет — 1. тырмалау; 2. тырмалау вакыты.

**БОРО'ТЬСЯ** *несов.*— көрәшү; алышу, тартышу, ярышу.

**БОРТ** *м.* (*мн.* бортá и бóрты) — 1. борт (а. пароходның, көймәнең, грузовикның һ. б. ян стенасы; б. бильярд өстәленең ян стенасы); 2. (*одежды*) каплама (киемнең төймәле яки элмәкле кырые). ◇ **Взять на борт** — пароходка кабул итү, палубага мендерү (кертү). **Человек за бортом!** — диңгездә кеше! Суда кеше бата! **Выбросить за борт** — чыгарып ташлау. **Борт о борт** — янәшә.

**БОРТЕВО'Й** — чолык...-ы, чолыклык...-ы; *бортевое хозяйство* — чолыклык хуҗалыгы (табигый, кыргый балчылык хуҗалыгы).

**БО'РТИ'ЩЕ** *ср. устар.*— бер дюжина; *бортище пуговиц* — бер дюжина сәдәп.

**БОРТМЕХА'НИК** *м.*— бортмеханик (очу аппаратында — самолётта, дирижабльдә, аэростатта — җиһазларның, аппаратларның һәм приборларның торышы һәм эше өчен җаваплы кеше).

**БО'РТНИК** *м.*— чолыкчы, чолык (балы) эзләүче.

**БО'РТНИЧАТЬ** *несов.*— чолыкчылык белән шөгыльләнү, чолык эзләү (урманда агач куышына урнашкан бал кортлары күчен эзләү һәм шулардан бал алу эше белән шөгыльләнү).

**БО'РТНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — чолыкчылык (чолык умартачылыгы, урман умартачылыгы); чолык (эзләү) кәсебе.

**БОРТОВО'Й** — ян...; *бортовая качка* — ян качка, ян-якка чайкалу (диңгез пароходында).

**БОРТЬ** *ж.*— 1. чолык (кыргый умарта кортлары оялаган агач куышы); 2. багана умарта.

**БОРЩ** *м.*— 1. борщ (чөгендер һәм башка яшелчәләр салып пешерелгән аш); 2. *к.* борщевик.

**БОРЩЕВИ'К** *м. бот.*— балтырган.

**БОРЬБА'** *ж. мн.* нет — көрәш.

**БОСИКО'М** *нареч.*— яланаяк, яланаяктан.

**БОСО'Й** — яланаяклы.

**БОСОНО'ГИЙ** — к. босой.

**БОСОНО'ЖКА** *ж.* — 1. яланаяклы кыз яки хатын; 2. яланаяк биюче артистка.

**БОСОНО'ЖКИ** *мн.*— босоножки (хатын-кызларның җәйге аяк киеме).

**БОСС** *м.*— босс (1. чит илләрдә — предприятие хуҗасы, учреждение хуҗасы, җитәкчесе; 2. АКШта республикачылар яки демократлар партиясенең берәр оешмасында җитәкчелек итүче).

**БОСТО'Н** *м.*— бостон (1. карта уены; 2. танец исеме; 3. *текст.* кыйммәтле юка йон тукыма).

**БО'СЫЙ** — к. босой.

**БОСЯ'К** *м. дореволюц.*— босяк, сукбай, йолкыш, зимагур.

**БОСЯ'ЦКИЙ** — сукбайлар...-ы, босяклар...-ы; *босяцкая песня* — сукбайлар җыры.

**БОСЯ'ЧЕСТВО** *ср.*— 1. сукбайлык, босяклык; 2. *собир.* босяклар, сукбайлар.

**БОСЯ'ЧКА** *ж.*— сукбай, йолкыш хатынкыз.

**БОТАНИЗИ'РОВАТЬ** *несов.*— үсемлекләр җыю (өйрәнү өчен).

**БОТА'НИК** *м.*— ботаник, ботаника белгече.

**БОТА'НИКА** *ж. мн.* нет — ботаника (үсемлекләр турындагы фән).

**БОТАНИ'ЧЕСКИЙ** —1. ботаник; *ботаническое название растения* — үсемлекнең ботаник атамасы; 2. ботаника...-ы; *ботанический сад* — ботаника бакчасы.

**БОТА'ТЬ** *несов.*— 1. гөмберләү, гөмбер белән болгату (балык тотканда суны); 2. шапылдау.

**БО'ТА'ЛО** *ср.*— 1. гөмбер, гөмбер колгасы (балык куу өчен); 2. зур кыңгырау (көтүдә йөри торган атка яки сыерга тагыла).

**БОТВА'** *ж. мн.* нет — сабак-яфрак, сабак.

**БОТВИ'НЬЯ** *ж. мн.* нет — ботвинья (квастан, пешерелгән яшелчәдән һәм балыктан хәзерләнгән салкын аш).

**БОТВОРЕ'ЗКА** *ж.* — сабак-яфрак кискеч (машина).

**БО'ТИКИ** *мн.* (*ед.* ботик) — к. боты.

**БОТИ'НКИ** *мн.* (*ед.* ботинок) — ботинка (аяк киеме).

**БОТФО'РТ** *м. устар.*— ботфорт (озын кунычлы итек).

**БО'ТЫ** *мн.*— боты (аяк киеме).

**БО'ЦМАН** *м. мор.*— боцман (диңгез пароходында барлык матросларның турыдантуры начальнигы).

**БОЧА'Г** *м. обл.*— су тулган чокыр; чоңгыл, тоба.

**БОЧА'Р** *м.*— к. бондарь.

**БОЧА'РИТЬ, БОЧА'РНИЧАТЬ** *несов.*— к. бондарить.

**БОЧА'РНЫЙ** — мичкә...-ы; *бочарный обруч* — мичкә кыршавы.

**БОЧА'РНЯ** *ж.*— мичкә ясау мастерское.

**БО'ЧЕЧНЫЙ** — мичкә...; *бочечное дно* — мичкә төбе.

**БО'ЧКА** *ж.*— мичкә. ◇ **Как сельди в бочке** — бик тыгыз, инә төртерлек урын да юк.

**БОЧКО'М** *нареч.*— к. боком.

**БОЧО'НОК** *м.*— кечкенә мичкә.

**БОЧО'НОЧНЫЙ** — мичкә...-ы; *бочоночный обруч* — мичкә кыршавы.

**БОЯЗЛИ'ВО** *нареч.*— куркып, куркып кына, кыюсыз гына.

**БОЯЗЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — куркаклык, куркучанлык, өркәклек.

**БОЯЗЛИ'ВЫЙ** — 1. куркак, куркучан, өркәк; 2. куркак кешегә хас.

**БО'ЯЗНО** *в знач. сказ.*— куркыныч.

**БО'ЯЗНЫЙ** *просторечн.*— к. боязливый.

**БОЯ'ЗНЬ** *ж. мн.* нет— курку, шүрләү, өркү.

**БОЯ'РИН** *м. (мн.* бояре) *истор.*— бояр.
**БОЯ'РСКИЙ** — боярлар...-ы; *боярская дума* — боярлар думасы.
**БОЯ'РСТВО** *ср. мн.* нет, *собир. истор.*— боярлар, боярлар сословиесе.
**БОЯ'РЩИНА** *ж. мн.* нет, *истор.*— **1.** к. барщина; **2.** боярлар хакимлеге.
**БОЯ'РЫНЯ** *ж. истор.*— бояр хатыны.
**БОЯ'РЫШНИК** *м. бот.*— дүләнә, камыр агачы.
**БОЯ'РЫШНЯ** *ж. истор.*— бояр кызы.
**БОЯ'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** курку, өркү, шүрләү; **2.** бозылу; *фотографические пластинки боятся света* — фотографик пластинкалар яктыдан бозылалар.
**БРА** *ср. нескл.*— стена шәмдәле (стенага беркетелгән электрик лампа кирәк-яраклары).
**БРАВА'ДА** *ж. мн.* нет— күрсәтмә батырлык, акылсыз батырлык; мәгънәсез кыланыш, әдәпсез кыланыш.
**БРАВИ'РОВАТЬ** *несов.*—әтәчләнү, кирәксезгә батырлык күрсәтү.
**БРА'ВО** I *нареч.*— егетләрчә; *браво закрутить усы* — мыекны егетләрчә бөтереп кую.
**БРА'ВО** II *межд.*— браво! яшә! шәп! афәрин! (оста башкарган өчен мактау сүзе).
**БРАВУ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — күтәренкелек, дәртлелек, җанлылык.
**БРАВУ'РНЫЙ** — күтәренке, дәртле, җанлы.
**БРА'ВЫЙ** — җитез, булдыклы, егетсымак.
**БРА'ГА** *ж.*— ачы бал, йорт сырасы, брага.
**БРАДОБРЕ'Й** *м. устар.*— чәч-мыек кыручы, сакал-мыек кыручы, чәч китәрүче, чәч алучы.
**БРА'ЖКА** *ж. мн.* нет — **1.** к. брага; **2.** сосла (спирт куу өчен хәзерләнгән сосла); **3.** *простореч.* эчү мәҗлесе.
**БРА'ЖНИК** I *м. устар.*— эчкече, исерекбаш.
**БРА'ЖНИК** II *м. зоол.*— балкарагы.
**БРА'ЖНИЧАТЬ** *несов. устар.*— эчеп йөрү, эчү.
**БРАЗДА'** *ж. устар.*— к. борозда.
**БРАЗДИ'ТЬ** *несов. устар.*— к. бороздить.
**БРАЗДЫ': бразды правления** — власть, идарә итү; *принять бразды правления* — властьны кабул итеп алу.
**БРАЗИ'ЛЕЦ** — бразилияле.
**БРАЗИ'ЛЬСКИЙ** — Бразилия...-ы; *бразильский пролетариат* — Бразилия пролетариаты.
**БРАЗИ'ЛЬЦЫ** *мн. (ед.* бразилец) — бразилиялеләр, Бразилия халкы.
**БРАК** I. *м.*— **1.** *(о мужчинах)* өйләнү; **2.** *(о женщинах)* кияүгә чыгу, тормышка чыгу.
**БРАК** II *м. мн.* нет — брак, бозык.
**БРАКЁР** *м.*— бракёр (товарның яраклылыгын билгеләүче).
**БРАКЕРА'Ж** *м. торг.*— бракераж (товарларның яраклылыгын һәм заказ шартларына туры килүен рәсми рәвештә танылау).
**БРАКОВА'ТЬ** *несов.*— **1.** бракка чыгару; **2.** *перен.* яраксызга чыгару, яраксыз дип табу.
**БРАКОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— **1.** бракка чыгарылу; **2.** *перен.* яраксызга чыгарылу.
**БРАКО'ВКА** *ж. мн.* нет — бракка чыгару; бракка чыгарылу.
**БРАКО'ВЩИК** *м.*, **БРАКО'ВЩИЦА** *ж.*— браковщик, бракка чыгаручы.
**БРАКОДЕ'Л** *м.*— брак ясаучы.
**БРАКОДЕ'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.*— брак ясау.
**БРАКОНЬЕ'Р** *м.*— браконьер (аучылык итү законнарын бозучы; аучылык итү тыелган урыннарда аучылык белән шөгыльләнүче).
**БРАКОНЬЕ'РСТВО** *ср. мн.* нет — браконьерлык.
**БРАКОРАЗВО'ДНЫЙ** *устар.*— аерылышу...-ы; *бракоразводное дело* — аерылышуны рәсмиләштерү эше.
**БРАКОСОЧЕТА'НИЕ** *ср. устар.*— никах, никахланышу.
**БРАНДАХЛЫ'СТ** *м. разг.*— **1.** начар, үтә сыек аш яки эчемлек; **2.** *перен. (дрянной человек)* начар, буш кеше.
**БРА'НДЕР** *м. устар.*— брандер (**1.** элек— яна торган материал тутырып һәм ут төртеп дошман корабльләренә җибәрелгән судно; **2.** хәзер — портка керү юлын бикләү өчен батырыла торган судно). ◇ **Запустить или подпустить брандера** *перен.* — талаш, гауга чыгару өчен берәр нәрсә әйтү.
**БРАНДМАЙО'Р** *м.*— брандмайор (шәһәрләрдә янгынга каршы көрәшүче командаларның башлыгы).
**БРАНДМА'УЕР** *м.*— брандмауер (янгыннан саклау өчен ике өй арасына салынган биек таш койма).
**БРАНДМЕ'ЙСТЕР** *м.* — брандмейстер (янгынга каршы көрәшүче команда башлыгы).
**БРАНДСПО'ЙТ** *м.* — брандспойт (**1.** пожар насосы; **2.** насос эчәгесе очына кертелгән сиптергеч).
**БРАНИ'ТЬ** *несов.*— орышу, ачулану, шелтәләү, тиргәү, әрләү.
**БРАНИ'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** ызгышу, сүгешү, тиргәшү, эрепләшү; **2.** сүгенү.
**БРА'ННЫЙ** I — сүгенү...-ы, оятсыз; *бранные слова* — сүгенү сүзләре (оятсыз сүзләр).
**БРА'ННЫЙ** II *устар.*— хәрби, сугыш...-ы; *бранное поле* — сугыш мәйданы.
**БРАНЧИ'ВЫЙ, БРАНЧЛИ'ВЫЙ** — эрепләшүчән, тиргәшүчән; сүгенүчән.
**БРА'НЫЙ** — чүпләмле (бизәкләп тукылган).
**БРАНЬ** I *ж. мн.* нет — сүгеш, тиргәш; сүгенү сүзләре, оятсыз сүзләр.
**БРАНЬ** II *ж. устар.*— сугыш; *на поле брани* — сугыш мәйданында.
**БРАСЛЕ'Т** *м.*, **БРАСЛЕ'ТКА** *ж.*— беләзек.

**БРАСЛЕ'ТНЫЙ** — беләзек...-ы; *браслетная застёжка* — беләзек каптырмасы.

**БРАСС** *м. спорт.* — брасс (йөзү стиле).

**БРАТ** *м. (мн.* братья) — 1. кардәш (бертуган абый, эне); *(старший)* абый, абзый, ага, абза; *(младший)* эне; 2. *только ед. (обращение)* туганкай; *ты, брат, мне зубы не заговаривай* — син, туганкай, миңа юкә чәйнәп тормa; син, туганкай, салпы якка сәлам кыстырма. ◇ **Двоюродный брат** — туганнан туган, тудыка (аталары яки аналары бертуган ир кардәшләр бер-беренә карата). **Молочный брат** — сөт кардәше, имчәктәш туган. **Сводный брат** — үги туган. **Наш брат** — безнең ишеләр. **Ваш брат** — сезнең ишеләр; *на вашего брата не угодишь* — сезнең ишеләргә ярый алмассың. **Свой брат**—үз кеше. **На брата**—кеше башына; *пришлось по целковому на брата* — кеше башына берәр сум туры килде.

**БРАТА'Н** *м. обл.* — туганнан туган; абый, ага, абзый.

**БРАТА'НЬЕ** *ср.* — к. брататься.

**БРАТА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. туганнарча мөнәсәбәткә керү, дуслашу; 2. туганлашу (сугыш вакытында бер-бере белән сугышучы ике ил гаскәре сугышчыларының татулашулары).

**БРАТВА'** *ж. мн.* нет, *собир.* — иптәшләр, туганнар, дуслар, егетләр (күбрәк, мөрәҗәгать иткәндә); *идём, братва!* — киттек, егетләр!

**БРА'ТЕЦ** *м.* — 1. энекәш; 2. туганкай.

**БРА'ТИ'НА** *ж. истор.* — чүмеч, тустаган (борынгы Россиядә туйларда аракы салып бирү өчен).

**БРАТИ'ШКА** *м.* — 1. эне, энекәш; 2. туганкай; *а, братишка, и ты здесь!* — ә, туганкай, син дә биредәмени!

**БРА'ТИЯ** *собир.* — 1. *простореч.* халык (бер профессия кешеләре); *пишущая братия* — язучылар халкы; 2. *церк.* бер монастырь монахлары.

**БРА'ТНИИ** *устар.*, **БРА'ТНИН** — абыйның, абыйныкы (эненең, энеңеке).

**БРАТО'К** *м.* — энекәш, туганкай.

**БРАТОЛЮБИ'ВЫЙ** — кешеләрне сөюче.

**БРАТОЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет — кешеләрне сөю.

**БРАТОУБИ'ЙСТВЕННЫЙ** — үзара үтерешү...-ы; *братоубийственная война* — үзара үтерешү сугышы.

**БРАТОУБИ'ЙСТВО** *ср. устар.* — 1. бертуганны үтерү; 2. үз сыйныф кешеләрен үтерү; якын, фикердәш кешеләрне үтерү.

**БРАТОУБИ'ЙЦА** *ж. устар.* — үз туганын үтерүче.

**БРА'ТСКИ, ПО-БРА'ТСКИ** *нареч.* — туганнарча, дусларча.

**БРА'ТСКИЙ** — 1. туганлык...-ы, кардәшлек...-ы; *братские чувства* — кардәшлек хисләре; 2. тугандаш; *братские республики* — тугандаш республикалар; 3. туганнарча; *братские отношения* — туганнарча мөнәсәбәт.

**БРА'ТСТВО** *ср.* — 1. туганлык, бердәмлек; 2. *рел.* дини җәмгыять.

**БРА'ТЦЫ** *мн.* — туганнар; иптәшләр, егетләр.

**БРАТЬ** *несов.* — 1. алу; *брать палку* — таяк алу; *брать взаймы* — бурычка (көтәргә) алу; *брать кого-н. в качестве примера* — кемне дә булса мисал итеп алу; 2. алдыру, уңышка ирешү; *он берёт умом* — ул акыл белән алдыра; 3. тоту; *бери вправо* — уңга тот; 4. кабу, чиртү; *рыба плохо берёт* — балык чиртми. ◇ **Брать верх** — өстен чыгу, өстенлек алу. **Брать на себя смелость** — батырчылык итү. **Брать прицел** — төбәү, төзәү. **Брать начало** — башланып китү, башлану; *река Кама берёт начало в Уральских горах* — Кама елгасы Урал тауларыннан башланып китә. **Брать своё** — үзенекен итү; *жизнь берёт своё* — тормыш үзенекен итә. **Нож не берёт** — пычак кисми, үтми. **Сила не берёт** — көч җитми. **Брать за горло** — якасыннан алу (мәҗбүр итү). **Брать за живое, за сердце** — нык тәэсир итү. **Брать в штыки** — штыкка алу (кискен каршылык күрсәтү). **Брать под руку** — култыклап алу. **Брать ягоды (грибы)** — җиләк (гөмбә) җыю. **Брать в оборот** — шелтәләү, кирәген бирү, арт сабагын укыту. **Тоска берёт** — эч поша. **Брать курс, направление** — юл тоту, юнәлеш алу. **Брать высоту** — күтәрелү (самолёт, дирижабль турында). **Брать одну сторону медали** — берьяклы гына аңлау, мәсьәләнең (эшнең) бер генә ягын күздә тоту. **Брать к сердцу** — борчылу, күңелгә якын алу.

**БРА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. тотыну; *не берись за перила: они только что выкрашены* — култыксага тотынма: ул әле генә буялган; 2. *страд.* алыну, түләтелү; 3. өскә алу, алыну, керешү; *я берусь помочь тебе* — мин сиңа ярдәм итәргә өстемә алам; 4. килеп чыгу; *я сама не понимаю, откуда бралось у меня такое спокойствие* — мондый тынычлык кайдан килеп чыкканын мин үзем дә аңламыйм. ◇ **Браться за ум** — акылга утыру.

**БРА'ТЬЯ** — 1. туганнар, агалы-энеле; 2. к. братия.

**БРА'УНИНГ** *м.* — браунинг (автомат рәвештә ата торган пистолет).

**БРАХМАНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — браһманизм (индуслар дине).

**БРА'ЧНЫЙ** — өйләнешү ... -ы; *брачные отношения* — өйләнешү мөнәсәбәтләре. ◇ **Брачный наряд, брачное оперение** — кавышу бизәнүе (аталану чорында кошларның һәм хайваннарның махсус каурый чыгарулары, койрык үстерүләре яки вакытлыча төсләрен үзгәртүләре). **Брачный вылет** — туйга очу (яшь ана кортның ата корт (соры корт) белән очрашу өчен умартадан чыгуы).

**БРЕВЕ'НЧАТЫЙ** — бүрәнә ..., бүрәнәдән ясалган; *бревенчатая стена* — бүрәнә стена.

**БРЕВНО'** *ср. (мн. брёвна)* — 1. бүрәнә; 2. *перен.* агач, утын (аңгыра, туң кеше).

**БРЕГ** *м. устар.* — к. берег.

**БРЕД** *м. мн.* нет — **1.** саташу (йокы арасында яки өндә авыру хәлендә); **2.** (*фантазия*) хыял (булмас эш), уйдырма.

**БРЕ'ДЕНЬ** *м.* — ятьмә, сөрәкә (балык сөзү өчен).

**БРЕДИ'НА** *ж. бот.* — вак тал, кәҗә талы.

**БРЕ'ДИТЬ** *несов.* — саташу, хыяллану; *больной бредит* — авыру саташа; *он бредит своей возлюбленной* — ул үзенең сөйгәне белән саташа (һаман аның турында уйлый, сөйли). ◇ **Не видит, не бредит** — уйлап та карамый. **И спит, и бредит** — өенендә дә, төшендә дә шуны гына күрә (гел шуның турында гына уйлый, бик каты уйлый).

**БРЕ'ДИТЬСЯ** *несов. редко* — саташу, күз алдына килү; *ему всё бредится летнее путешествие* — ул һаман җәйге сәяхәт белән саташа, аның күз алдына һаман җәйге сәяхәт килә.

**БРЕ'ДНИ** *ед.* нет — сафсата, хыяллар, юкбарлар, уйдырмалар.

**БРЕДОВО'Й** — хыялый; *бредовая идея* — хыялый идея.

**БРЕ'ЗГАТЬ** *несов.* — **1.** җирәнү, чиркану; **2.** *перен.* тайчану, тартыну; *ничем не брезгает* — максатына ирешү өчен бернәрсәдән дә тайчанмый, тартынмый.

**БРЕЗГЛИ'ВЕЦ** *м.*, **БРЕЗГЛИ'ВИЦА** *ж.* — җирәнүчән, чиркануган.

**БРЕЗГЛИ'ВО** *нареч.* — җирәнеп, чирканып.

**БРЕЗГЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — җирәнүчәнлек, чирканучанлык.

**БРЕЗГЛИ'ВЫЙ** — **1.** җирәнүчән, чирканучан; *брезгливый человек* — җирәнүчән кеше; **2.** җирәнеч, чирканыч, җирәнеп... -ы, җирәну... -ы; *брезгливое чувство* — җирәнү хисе; *брезгливый взгляд* — җирәнеп карау.

**БРЕ'ЗГОВАТЬ** *несов.* — к. брезгать.

**БРЕЗГУ'Н** *м.*, **БРЕЗГУ'НЬЯ** *ж. фам. разг.* — к. брезгливец.

**БРЕЗЕ'НТ** *м.* — брезент (су үткәрми торган тукыма).

**БРЕЗЕ'НТНЫЙ** — к. брезентовый.

**БРЕЗЕ'НТОВЫЙ** — **1.** брезент...- ы; брезент эшләп чыгара торган; *брезентовое производство* — брезент производствосы; **2.** брезент..., брезенттан эшләнгән; *брезентовый плащ* — брезент плащ.

**БРЕ'ЗЖИТЬ, БРЕ'ЗЖИТЬСЯ** *несов.* — таң ату, таң беленү, яктыра башлау; яктырып килү; жем-жем итеп күренү; *в степи чуть брезжит огонёк* — далада жемжем итеп ут күренә.

**БРЕЛО'К** *м.* — брелок (кесә сәгате чылбырына тагыла торган вак-төяк бизәкләр).

**БРЕЛО'ЧНЫЙ** — брелок .. .-ы; *брелочный камень* — брелок ташы.

**БРЕМЕНИ'ТЬ** *несов. устар.* — авырлык салу, авырлык китерү, борчу, мәшәкатьләү.

**БР'ЕМЯ** *ср.* — авырлык, йөк. ◇ **Разрешиться от бремени** — бала табу, йөктән (баладан) котылу. **Под бременем** — изүе астында, җәбере астында.

**БРЕ'ННЫЙ** *устар.* — чери торган, черегән, фани; *бренный мир* — фани дөнья.

**БРЕНЧА'ТЬ** *несов.* — **1.** шылтырау, шалтырау, чыңгырау, челтерәү, чалтыр-чолтыр килү; **2.** дыңгырдату (музыка коралында уйный белми уйнау).

**БРЕСТИ'** *несов.* — **1.** (*итти с трудом*) сөйрәлеп бару, көчкә-көчкә генә атлау; **2.** (*итти тихо*) әкрен генә китеп бару, кайтып килү, уйланып китеп бару (кайтып килү); *откуда, умная, бредёшь ты, голова?* — кайдан син, акыллы баш, әкрен генә кайтып киләсең?

**БРЕТЕ'ЛЬ** *ж.* — бретель (күлмәкне, юбканы тотып тору өчен җилкә аша үткәрелгән тасма).

**БРЕТЁР** *м. устар.* — бретёр, гаугачы, җәнҗалчы (дуэльгә чакыру өчен кечкенә генә булса да сылтау эзләүче, дуэльдә сугышырга яратучы).

**БРЕХ** *м.* — **1.** эт өрүе; **2.** к. брехня.

**БРЕХА'ТЬ** *несов. простореч.* — **1.** өрү; **2.** *перен.* ялганлау; яла ягу. ◇ **Собака брешет, ветер носит** — эт өрер, бүре йөрер.

**БРЕХНЯ'** *ж. мн.* нет — ялган, буш сүз, сафсата, уйдырма.

**БРЕХУ'Н** *м. простореч.* — лыгырдык, алдакчы, ялганчы.

**БРЕШЬ** *ж.* — **1.** тишек, җимерек, ярык (крепость стенасында снаряд ярылудан); **2.** *перен.* зарар, зыян, кимчелек. ◇ **Пробить брешь** — кыенлыкны ерып чыгу.

**БРЕ'ЮЩИЙ** — кыручы (сакалны, мыекны). ◇ **Бреющий полёт** — кырдырып очу (самолётта бик түбәннән, дошман гаскәрләренә пулемёттан ата-ата очу).

**БРИГ** *м. устар. мор.* — бриг (ике мачталы җилкәнле судно).

**БРИГА'ДА** *ж.* — бригада (**1.** гаскәри берләшмә; флотның берничә хәрби корабльдән тора торган часте; **2.** поездга хезмәт күрсәтүче кондукторлар составы; **3.** билгеле бер эшне күмәкләп башкаручылар коллективы, мәсәлән, колхозда).

**БРИГАДИ'Р** *м.* — бригадир (**1.** бригада житәкчесе; **2.** электә полковник белән генерал арасындагы гаскәри чин).

**БРИГА'ДНЫЙ** — бригада ... -ы; *бригадный комиссар* — бригада комиссары.

**БРИГАНТИ'НА** *ж. истор. мор.* — бригантина (җилкәнле җиңел судно).

**БРИЗА'НТНЫЙ** *устар.* — бризант, һавада шартлый торган; *бризантный снаряд* — бризант снаряд (һавада ярылып осколоклар сибә торган снаряд).

**БРИКЕ'Т** *м.* — брикет (күмер, пычкы чүбе, металл йомычкасы кебекләрдән эскәнҗәгә кыстырып ясалган кирпеч, кисәк).

**БРИКЕТИ'РОВАНИЕ** *ср.* — брикет ясау, брикет сугу.

**БРИКЕТИ'РОВАТЬ** *несов.* — брикетлау, брикет хәленә китерү.

**БРИЛЛИА'НТ, БРИЛЬЯ'НТ,** *м.* — брильянт (махсус шомартылган алмаз).

**БРИЛЛИА'НТОВЫЙ, БРИЛЬЯ'НТОВЫЙ** — **1.** брильянт...; *бриллиантовый перстень* — брильянт йөзек; **2.** брильянтлы, брильянт белән бизәлгән; *брильянтовые серьги* — брильянтлы алка.

**БРИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — бриология (ботаниканың мүкләрне өйрәнә торган бүлеге).

**БРИСТО'ЛЬ, БРИСТО'ЛЬСКИЙ КАРТО'Н** — бристоль (югары сорт кәгазь табакларын бер-берсенә ябыштырып ясалган картон).

**БРИТА'НСКИЙ** — Британия ... -ы; *Британские острова* — Британия утраулары.

**БРИТА'НЦЫ** *мн.(ед.*британец)—к. бритты.

**БРИ'ТВА** *ж.*— бритва.

**БРИ'ТВЕННИЦА** *ж.*— кырыну приборы.

**БРИ'ТВЕННЫЙ** — кырыну ...-ы; *бритвенный прибор* — кырыну приборы.

**БРИ'Т (Т)Ы** — бритлар (хәзерге Англия территориясендә яшәгән борынгы кельт халкы).

**БРИТЬ** *несов.*— кыру, алу, китәрү (чәчне, сакалны, мыекны). ◇ **Так и бреет, так и бреет** — әйтә дә сала, әйтә дә сала (оста җавап бирә).

**БРИТЬЁ** *ср. мн. нет* — кырыну.

**БРИ'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** кырыну; **2.** *(не носить бороды и усов)* кырынып йөрү.

**БРИ'ЧКА** *ж.*— бричка (җиңел арба).

**БРО'ВНЫЙ** — каш ...-ы; *бровные дуги* — каш кыйгачлары.

**БРОВЬ** *ж.*— каш. ◇ **Не в бровь, а (прямо) в глаз** — нәкъ өстенә басты (тапкыр сүз турында).

**БРОД** *м.*— кичү (елганың җәяүләп яки ат белән үтәрлек сай урыны). ◇ **Не зная броду, не суйся в воду** — үзең белмәгән эшкә тотынма.

**БРОДИ'ЛО** *ср.*— чүпрә, оеткы; ачыткы.

**БРОДИ'ЛЬНЫЙ** — **1.** әчү ... -ы; *бродильный процесс*—әчү процессы; 2. әчетү ...-ы; *бродильный чан* — әчетү чаны.

**БРОДИ'ЛЬНЯ** *ж.*— әчетү бүлмәсе (спирт заводында).

**БРОДИ'ТЬ** I *несов.* — йөрү, әрле-бирле йөрү; *старик еле бродит* — карт чак-чак кына йөри; *охотники бродили весь день по колено в воде* — аучылар көне буе тездән суда йөрделәр. ◇ **На лице её бродила улыбка** — аның йөзендә елмаю сизелә иде, ул көлемсерәп тора иде.

**БРОДИ'ТЬ** II *несов.*— әчү, кабару, күперү, чемердәү (әчегәндә).

**БРОДИ'ТЬ** III *несов. обл.*— ятьмә белән балык сөзү.

**БРОДЯ'ГА** *м.*— сукбай, йолкыш, зимагур.

**БРОДЯ'ЖЕСТВО** *ср. мн. нет* — к. бродяжничество.

**БРОДЯ'ЖИЙ** *м.*— зимагурлар ...-ы; йолкышлар ... -ы; *бродяжий быт* — зимагурлар тормышы.

**БРОДЯ'ЖИТЬ** *несов. просторен.* — к бродяжничать.

**БРОДЯ'ЖКА** *ж.*—**1.** к. бродяга; **2.** хәерче, соранучы хатын.

**БРОДЯ'ЖНИЧАТЬ** *несов.*— сукбайлыкта йөрү.

**БРОДЯ'ЖНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — зимагурлык, сукбайлык.

**БРОДЯ'ЖНЫЙ** *просторен.*— к. бродяжий.

**БРОДЯ'ЧИЙ** — күчмә, күчеп йөри торган; гизүче, сәйяр; күчеп йөрергә яратучан. ◇ **Бродячая собака** — иясез эт, адашкан эт.

**БРОЖЕ'НИЕ** *ср.*—**1.** *биохим.* әчү, кабару, күперү; **2.** *полит.* чуалыш, кузгалыш, буталыш, ризасызлык.

**БРО'МИСТЫЙ** — бромлы; *бромистый натр* — бромлы натр.

**БРО'МОВЫЙ** — бром ... -ы; *бромовый завод* — бром заводы.

**БРОНЕАВТОМОБИ'ЛЬ** *м.*— бронялы автомобиль.

**БРОНЕБО'ЙНЫЙ** — бронятишкеч; *бронебойный снаряд* — бронятишкеч снаряд.

**БРОНЕБО'ЙЩИК** *м.* — бронебойщик, бронебойчы.

**БРОНЕВИ'К** *м.*— броневик (**1.** бронялы автомобиль; **2.** бронялы частьларда хезмәт итүче гаскәри).

**БРОНЕВО'Й** — бронялы; *броневой автомобиль* — бронялы автомобиль.

**БРОНЕНО'СЕЦ** *м. мор.* — броненосец (бронялы сугыш корабле).

**БРОНЕНО'СНЫЙ** — бронялы.

**БРОНЕПО'ЕЗД** *м. воен.* — бронепоезд, бронялы поезд.

**БРОНЕСИ'ЛЫ** *воен.*— бронялы көчләр (броня белән капланган туплар, машиналар).

**БРОНЕТА'НКОВЫЙ** *воен.*— бронетанк ... -ы; *бронетанковые силы* — бронетанк көчләре (гаскәрләре).

**БРО'НЗА** *ж.*— бронза (**1.** бакыр, ак кургашын һ. б. металлар эретмәсе; **2.** бронзадан ясалган әйберләр).

**БРОНЗИРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— **1.** бронзалау, бронза йөгертү; **2.** бронза төсенә буяу.

**БРОНЗИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — **1.** бронзалану, бронза йөгертелү; **2.** бронза төсенә буялу.

**БРО'НЗОВЫЙ** — бронза...., бронзадан ясалган; *бронзовый памятник* — бронза һәйкәл.

**БРОНИ'РОВАТЬ** —**1.** *сов.* и *несов. воен.* бронялау, броня белән каплау, корыч белән тышлау; **2.** *несов.* бронировать итү, беркетү, беркетеп кую (бронь буенча гына бирү өчен аерып кую, мәсәлән, поезддагы урынны, гостиницадагы номерны һ. б.).

**БРОНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— бронировать ителү; *для больных бронируются железнодорожные билеты* — авырулар өчен тимер юл билетлары бронировать ителәләр.

**БРО'НХИ** *м. мн. анат.*— бронхлар (сулыш юлларының үпкәдәге тармаклары).

**БРОНХИА'ЛЬНЫЙ** *анат.* — бронхиаль, бронх ... -ы; *бронхиальные железы* — бронхиаль бизләр, бронх бизләре.

**БРОНХИ'Т** *м. мед.*— бронхит (бронхларның ялкынсынуы).

**БРО'НЯ** *ж.* — бронь (берәр нәрсәне, мәсәлән, поезддагы урынны, беркетү турындагы документ).

**БРОНЯ'** *ж.* — броня (1. *истор.* борынгыда сугышчыларга кидерү өчен металлдан ясалган кием; 2. *воен.* автомобильләрне һ. б. тышлау өчен корычтан ясалган плита).

**БРОСА'ТЕЛЬНЫЙ** — ыргыта торган, чөя торган.

**БРОСА'ТЬ** *несов.*— 1. ыргыту, ташлау; атып бәрү, ату, чөю; *бросать камень* — таш ыргыту; 2. чәчү, сибү; *солнце бросает лучи* — кояш нурларын чәчә; 3. чыгару, җибәрү; *бросать товар на рынок* — базарга товар чыгару; *бросать лучшие силы на слабый участок фронта* — иң яхшы көчләрне фронтның йомшак участогына җибәрү; 4. ташлау, ташлап китү, калдырып китү; *бросать имущество на произвол судьбы* — милекне язмыш ихтыярына (кочагына) ташлау (калдырып китү); 5. ташлау, туктату; *бросать курить* — тәмәке тартуны ташлау; 6. туздыру, әрәм-шәрәм итү; *он бросает деньги на ветер* — ул акчаны юкка туздыра, әрәм-шәрәм итә; 7. *безл.* селкетү, чайкалдыру. ◇ **Бросать тень** *перен.* — яман атлы итү, йөзгә кара ягу. **Бросать взгляд** — күз ташлау. **Бросать жребий** — шобага салу, шобага тоту. **Меня бросает в пот** — тирләтә, тирлим. **Меня бросает то в жар, то в холод** — тәнем эссе-ле-суыклы булып китә. **Бросать свет** *перен.*— яктырту, ачыклау. **Бросать в чей-н. огород камешки** — кемнең дә булса бакчасына таш ыргыту (кешегә төрттереп әйтү, тешләп әйтү мәгънәсендә).

**БРОСА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. ыргытышу, бәрешү, атышу; *бросаться камнями* — таш ыргытышу, таш бәрешү; 2. ташлану, ыргылу; *собаки бросаются на прохожих* — этләр үтеп баручыларга ташланалар; 3. йөгерү, китү; *кровь бросается в лицо* — йөзгә кан йөгерә; *вино бросается в голову* — аракы башка китә; 5. *страд.* ыргытылу, ташлану. ◇ **Бросаться в глаза** — күзгә ташлану, күзгә бәрелеп тору. **Бросаться словами** — уйламыйча сөйләү, авыз әйткәнне колак ишетмәү.

**БРО'СИТЬ** *сов.* — к. бросать. ◇ **Брось, бросьте** — ташла, ташлагыз, кирәкми. **Хоть брось** — бернәрсәгә дә ярамый.

**БРО'СИТЬСЯ** *сов.*—1. ташлану; 2. йөгерү; 3. тотыну, башлау; *броситься что-н. делать* — берәр нәрсә эшләргә тотыну. ◇**Броситься со всех ног** — җан-фәрманга йөгерә башлау. **Броситься в глаза** — күзгә чалыну, күзгә күренү, күзгә бәрелү.

**БРО'СКИЙ** — күзгә бәрелеп тора торган, җете ачык (мәсәлән, төс).

**БРОСКО'М** *нареч.* — бер сикерүдә, бер омтылуда; селтәп, чөеп.

**БРО'СОВЫЙ** — яраксыз, начар сыйфатлы. ◇**Бросовый экспорт**— к. демпинг.

**БРОСО'К** *м.*— бер сикерү, бер ыргылу, ыргылыш, ыргылу; бер ташлану; *гонщик-велосипедист сделал бросок на самом финише и пришёл первым* — велосипедта узышучы финишка килеп җиткәндә генә бер ыргылыш ясады да беренче булып килде.

**БРОШИРОВА'ТЬ, БРОШИРО'ВОЧНЫЙ** — к. брошюровать, брошюровочный.

**БРО'ШКА, БРОШЬ** *ж.*— брошка (зиннәтле булавка).

**БРОШЮ'РА** *ж.*— брошюра (кечкенә китап).

**БРОШЮРОВА'ЛЬНЫЙ** — китап төпләү ... -ы, брошюровать итү ... -ы; *брошюровальный станок* — китап төпләү (брошюровать итү) станогы.

**БРОШЮРОВА'ТЬ** *несов.*— китап төпләү, брошюровать итү.

**БРОШЮРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*—төпләнү, брошюровать ителү.

**БРОШЮРО'ВОЧНАЯ** — брошюровка бүлмәсе

**БРОШЮРО'ВОЧНЫЙ** — китап төпләү ... -ы, брошюровать итү... -ы; *брошюровочный цех* — китап төпләү (брошюровать итү) цехы.

**БРОШЮРО'ВЩИК** *м.*, **БРОШЮРО'ВЩИЦА** *ж.*— китап төпләүче, брошюровать итүче.

**БРУС** *м.* (*мн.* брусья) —1. борыс (дүрт кырлы озынча агач, таш яки металл кисәге); 2. кайрак, беләү; янавыч.

**БРУСКО'ВЫЙ** — дүрт кырлы; кисәкле; *брусковое мыло* — кисәкле сабын.

**БРУСНИ'КА** *ж. мн.* нет — нарат җиләге.

**БРУСНИ'ЧНИК** *м.*— нарат җиләклеге.

**БРУСНИ'ЧНЫЙ** — нарат җиләге ... -ы; *брусничный куст* — нарат җиләге куагы; *брусничное варенье* — нарат җиләге вареньесы.

**БРУСОВА'ТЬ** *несов.*— агачтан (таштан) кырып борыслар ясау.

**БРУСО'К** *м.*— 1. (*точильный камень*) кайрак, беләү, янавыч; 2. (дүрт кырлы) кисәк; *брусок мыла* — сабын кисәге, бер кисәк сабын.

**БРУСО'ЧНЫЙ** — кайрак...-ы; *брусочное производство* — кайрак производствосы.

**БРУСЧА'ТКА** *ж. мн.* нет — таш кирпеч (урамга җәю өчен кирпеч формасында кырылган таш).

**БРУСЧА'ТЫЙ** — борыслардан ясалган.

**БРУ'ТТО** — брутто (товарның савыты — ящигы, тартмасы, банкасы һ. б. белән бергә алынган авырлыгы).

**БРУЦЕЛЛЁЗ** *м. мед.*— бруцеллёз (терлекләрдә була торган йогышлы авыру; кешеләргә дә йога).

**БРЫЖЕ'ЙКА** *ж. анат.*— җыерча, мезентерий (корсакта эчәкләрне тотып тора торган катлау).

**БРЫЗГА'ЛКА** *ж.*, **БРЫЗГА'ЛО** *ср. спец.*— сиптергеч, бөркегеч.

**БРЫ'ЗГАТЬ** *несов.*— 1. сиптерү; *фонтан брызжет* — фонтан сиптерә; 2. чәчрәү; *искры брызжут из-под молота* — чүкеч астыннан очкыннар чәчри; 3. бөркү, чәчрәтү; *не брызгай на меня водой* — миңа су бөркемә, чәчрәтмә; 4. чәчрәп чыгу; *кровь брызжет* — кан чәчрәп чыга. ◇ **Брызжет счастье** — бәхет ташып тора. **Брызжет молодость** — яшьлек агып тора.

**БРЫ'ЗГАТЬСЯ** *несов.*— **1.** чәчрәтү, сибү, бөркү; **2.** *(друг в друга)* чәчрәтешү, сибешү, бөркешү.

**БРЫ'ЗГИ** *ед.* нет — чәчрәгән тамчылар, бөркелгән су тамчылары; вак бөртекләр, кисәкләр (суккан вакытта каты предметтан (мәсәлән, таштан) чәчри торган вак кисәкләр).

**БРЫ'ЗГИВАТЬ** *несов. многокр.*— чәчрәткәләү, сипкәләү.

**БРЫ'ЗНУТЬ** *сов.*— **1.** чәчрәтеп җибәрү; **2.** *(о дожде)* кинәтява башлау; **3.** йөгерешеп таралып китү; *ребятишки брызнули врассыпную* — балалар төрле якка йөгерешеп таралып киттеләр; **4.** чәчрәп чыгу; *кровь брызнула* — кан чәчрәп чыкты.

**БРЫКА'ТЬ** *несов.*— тибү (ат, сыер турында).

**БРЫКА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** тибү, тибенү; тыпырчыну; **2.** *(лягать друг друга)* тибешү; **3.** *перен.* киреләнү; *не брыкайся, а делай, что говорят* — киреләнмә, нәрсә әйтсәләр, шуны эшлә.

**БРЫКЛИ'ВЫЙ** — типкәк, тибешкәк, тибешүчән, тибешә торган.

**БРЫКНУ'ТЬ** *сов.*— тибеп җибәрү (ат турында).

**БРЫКУ'Н** *м.*, **БРЫКУ'НЬЯ** *ж.*— типкәк, тибешкәк.

**БРЫЛЯ'СТЫЙ** — салынкы иренле (эт).

**БРЫ'НЗА** *ж. мн.* нет — брынза (сарык сөтеннән ясалган эремчексыман сыр).

**БРЫСЬ!** *межд.*— перес!

**БРЮЗГА'** *м.* и *ж.*— мыгырдык, берәзгә (кеше).

**БРЮЗГЛИ'ВО** *нареч.*— мыгырдап, сукранып.

**БРЮЗГЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — мыгырдаучанлык, сукрануча́нлык, тар холыклылык.

**БРЮЗГЛИ'ВЫЙ** — мыгырдаучан, тар холыклы, сукранучан, берәзгә.

**БРЮ'ЗГНУТЬ** *несов.*— шешенү.

**БРЮЗЖА'ТЬ** *несов.*— мыгырдау, мыгырдану.

**БРЮ'КВА** *ж. бот.*— гәрәнкә, бүкән шалкан.

**БРЮ'КВЕНИЦА** *ж. зоол.*— гәрәнкә күбәләге.

**БРЮ'КВЕННЫЙ** — гәрәнкәдән хәзерләнгән; *брюквенный гарнир* — гәрәнкәдән хәзерләнгән гарнир.

**БРЮ'КВИНА** *ж.* — бер баш гәрәнкә.

**БРЮ'КИ** *ед.* нет — брюки, чалбар.

**БРЮНЕ'Т** *м.*— брюнет (кара чәчле ир кеше).

**БРЮНЕ'ТИСТЫЙ** — кара чәчле.

**БРЮНЕ'ТКА** *ж.*— брюнетка (кара чәчле хатын-кыз).

**БРЮХА'Н** *м.*— зур корсак(лы), кап-корсак.

**БРЮХА'СТЫЙ** — корсаклы.

**БРЮХА'ТАЯ** *простореч.*— көмәнле, корсаклы, балага узган, йөкле, авырлы.

**БРЮХА'Ч** *м.*— к. брюхан.

**БРЮ'ХО** *ср.*— корсак, эч.

**БРЮХОВИ'НА** *ж.*— кырык карта, зур ашказаны (күшәүче хайваннарда).

**БРЮ'ЧНЫЙ** — чалбар...-ы; *брючный цех* — чалбар цехы.

**БРЮШИ'НА** *ж. анат.*— корсак ярысы.

**БРЮШИ'ННЫЙ** — корсак ярысы ... -ы; *брюшинный нерв* — корсак ярысы нервысы.

**БРЮШКО'** *ср.*— **1.** *разг. шутл.* корсак; **2.** корсак асты тиресе (мехы).

**БРЮШНО'Й** — корсак ... -ы; *брюшной тиф* — корсак тифы; *брюшная полость* — корсак куышлыгы.

**БРЯК** *межд.*— шалтырт! доңгырт! чылтырт! *кто-то бряк в окно* — кемдер тәрәзәгә чылтырт!

**БРЯ'КАТЬ** *несов.*— шалтырату, чылтырату.

**БРЯ'КАТЬСЯ** *несов.*— к. брякнуться.

**БРЯ'КНУТЬ** *сов.*—**1.** шалтыратып җибәрү, шалтыратып кую, чылтыратып җибәрү, чылтыратып кую; **2.** шап иттереп төшерү, шап иттереп төшереп җибәрү; *брякнул вязанку дров на пол* — бер кочак утынны шап иттереп идәнгә төшерде; **3.** *фам.* урынсыз сүз ычкындыру, әйтеп салу; *и зачем он это брякнул при стариках?* — ни өчен инде ул моны картлар алдында әйтеп салды?

**БРЯ'КНУТЬСЯ** *сов.*— шап итеп төшү, шап итеп егылу, дөпелдәп егылу.

**БРЯЦА'ТЬ** *несов.*— шалтырау, чыңгырдау; шалтырату, чыңгырдату. ◇ **Бряцать оружием** —корал белән янау, сугыш белән куркыту.

**БУ'БЕН** *м.* — шөлдерле барабан (музыкаль инструмент).

**БУБЕНЦЫ'** *мн.* (*ед.* бубенец) — шөлдер, кечкенә кыңгырау.

**БУБЕ'НЧИК** *м.* — **1.** кечкенә шөлдер; **2.** *бот.* кыңгырау чәчәк; **3.** *перен.* лыгырдык, бушбугаз.

**БУ'БЛИК** *м.*— бублик (келиндер).

**БУ'БЛИКОВЫЙ, БУ'БЛИЧНЫЙ** — бублик ...-ы; *бубличное тесто* — бублик камыры.

**БУБНИ'ТЬ** *несов.* — мыгырдау, мыгыр-мыгыр килү.

**БУГА'Й** *м.* — **1.** үгез (Украинада һәм Көньяк Россиядә); **2.** к. выпь; **3.** *устар.* таран (электә крепость стенасын вату өчен кулланылган махсус бүрәнә).

**БУГО'Р** *м.*— калкулык, калку җир.

**БУГОРО'К** *м.* — **1.** кечкенә калкулык; **2.** төерчек, кабарчык.

**БУГО'РЧА'ТЫЙ** — төерчекле, төерчекләр белән капланган.

**БУГРИ'СТЫЙ** — калкулыклы, калкулыклар белән капланган.

**БУДДИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *рел.*— буддизм, Будда дине.

**БУДДИ'ЙСКИЙ** *рел.* — будда... -ы; *буддийский храм* — будда храмы.

**БУДДИ'СТ** *м.*, **БУДДИ'СТКА** *ж. рел.*— буддист, буддистка, будда динен тотучы.

**БУ'ДЕ** *союз устар.*— әгәр, әгәренки.

**БУ'ДЕТ** —**1.** быть фигыленең 3 нче заты; **2.** булыр, житәр, ташлагыз; *будет вам*

*разговаривать, спать мешаете* — житәр инде сөйләшмәгез, йокларга бирмисез.

**БУДИ'ЛЬНИК** *м.* — будильник (сәгать).

**БУДИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. *устар.* ачулану, ирен турсайту; 2. котырту, коткы салу.

**БУДИ'ТЬ** *несов.* — 1. уяту, йокыдан уяту; 2. *перен.* уяту, дәртләндерү, кузгату, ярсыту.

**БУДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — уятылу.

**БУ'ДКА** *ж.* — будка (сакчы куышы, сакчы өйчеге).

**БУ'ДНИ** *мн.* (*ед.* будень) — 1. эш көне 2. *перен.* (*беспросветная жизнь*) күңелсез, шатлыксыз көннәр (тормыш).

**БУ'ДНИЙ** — к. будничный 1.

**БУДНИ'ЧНЫЙ** — 1. эш ... -ы; көндәлек...; *будничный день* — эш көне; *будничная работа* — көндәлек эш; 2. *перен.* эчпошыргыч, соры, шатлыксыз, күңелсез; *будничная жизнь* — эчпошыргыч тормыш, күңелсез тормыш.

**БУДОРА'ЖИТЬ** *несов.* — тынгысызлау, тынычсызлау, борчу, бимазалау, ыгы-зыгы куптару.

**БУДОРА'ЖИТЬСЯ** *несов.* — тынычсызлану, борчылу, ыгы-зыгы килү.

**БУ'ДОЧНИК** *м. истор.* — будочник, бутишник (революциягә кадәр — будка янында постта торучы полицейский).

**БУ'ДТО** — 1. *союз (словно)* кебек, шикелле, ...-дәй, гүя, гүяки, әйтерсең; *лежит, будто мёртвый* — үлгән кебек ята; 2. *(в значении „что“)* дип; *он рассказывает, будто был на войне* — ул сугышта булдым дип сөйли; 3. *частица* бугай; *посмотри, будто идёт кто-то* — кара, кемдер килә бугай; 4. *вопр. частица* ... -мыни, шулаймыни; *я виноват будто?* — мин гаеплеменн? *Он хочет с тобой проститься.* — *Будто?* — ул синең белән саубуллашырга тели. — Шулаймыни? ◇ **Будто, будто бы** — имеш; *ей снится, будто бы она идёт по снеговой поляне* — аның төшенә керә: ул кар белән капланган алан буйлап бара имеш.

**БУДУА'Р** *м. устар.* — будуар (1. бай хатынының киенү-бизәнү бүлмәсе; 2. шул бүлмәдәге әйберләр).

**БУДУА'РНЫЙ** — будуар ...-ы; *будуарная мебель* — будуар мебеле.

**БУ'ДУЧИ** — буларак, булып та, булган хәлдә.

**БУ'ДУЩЕЕ** *ср. в знач. сущ.* — киләчәк; *насколько я был прав, покажет будущее* — минем ни дәрәҗәдә хаклы булганымны киләчәк күрсәтер; *светлое коммунистическое будущее* — якты коммунистик киләчәк.

**БУ'ДУЩИЙ** — 1. киләчәк, булачак, алдагы, киләчәктә булачак; *будущее поколение* — киләчәк буын; 2. киләсе; *на будущий год* — киләсе елга, яренгә. ◇ **Будущее время** *лингв.* — киләчәк заман.

**БУ'ДУЩНОСТЬ** *ж. мн.* нет — киләчәк; *будущность сельского хозяйства* — авыл хуҗалыгының киләчәге.

**БУ'ЕР** *м.* — 1. *спорт.* җилкәнле чана (бозда шуу өчен); 2. *мор.* җилкәнле кечкенә көймә.

**БУЕРА'К** *м.* — ерганак, су ерган чокыр.

**БУЖЕНИ'НА** *ж. мн.* нет — дуңгыз ите (кубесенчә пешкәне).

**БУЗА'** I *ж. мн.* нет, *просторечь.* — гауга, җәнҗал, ызгыш, дау, тәртипсезлек.

**БУЗА'** II *ж. мн. нет* — буза (Кырымда, Кавказда — исерткеч эчемлек).

**БУЗА'** III *ж.* — таштоз.

**БУЗИ'ЛА, БУЗИ'ЛО, БУЗИ'ЛЬЩИК** *м.* — гаугачы, дау күтәрүче, тәртип бозучы, җәнҗалчы.

**БУЗИНА'** *ж. мн.* нет, *бот.* — аю баланы, карга миләше.

**БУЗИ'ННИК** *м.* — аю баланлыгы, карга миләшлеге.

**БУЗИ'ННЫЙ, БУЗИ'НОВЫЙ** — аю баланы... -ы; *бузинный куст* — аю баланы куагы.

**БУЗИ'ТЬ** *несов.* — шау-шу күтәрү, гауга чыгару, җәнҗал куптару, тавыш чыгару, дау куптару.

**БУЗОВА'ТЬ** *несов. просторечь.* — тукмаклау, кыйнау, дөмбәсләү.

**БУЗОТЁР** *м.*, **БУЗОТЁРКА** *ж. просторечь.* — дау куптаручы, җәнҗалчы, җәнҗал чыгаручы, эшкә комачаулык итүче.

**БУЗОТЁРСТВО** *ср. мн.* нет — дау куптару, җәнҗал чыгару, тәртип бозу.

**БУЙ** *м. мор.* — буй, калкавыч (сай яки балыкчы ятьмәләре салынган урынны күрсәтү өчен).

**БУ'ЙВОЛ** *м. зоол.* — буйвол (Кавказда эш үгезе).

**БУ'ЙВОЛИЦА** *ж. зоол.* — ана буйвол.

**БУ'ЙВОЛОВЫЙ** — буйвол... -ы; *буйволовая кожа* — буйвол тиресе (күне).

**БУ'ЙНО** *нареч.* — 1. *(очень сильно)* көчле рәвештә, каты рәвештә; 2. *(очень быстро)* котырып, ду килеп.

**БУ'ЙНЫЙ** — 1. *(непокорный, шумный)* котырынкы, гаугачыл, буйсынмас; 2. көчле, каты, җимергеч; *буйный ветер* — көчле (каты) җил; 3. тиз, көчле, котырып (үсү турында); *буйный рост трав* — үләннәрнең тиз (көчле, котырып) үсүе.

**БУ'ЙСТВО** *ср.* — җәнҗал, гауга.

**БУ'ЙСТВОВАТЬ** *несов.* — котырыну, дау кубару, җәнҗал чыгару, холыксызлану.

**БУК** *м.* — 1. *(щелок)* селте; 2. *(кадка для бучения)* кисмәк.

**БУ'КА** *м.* и *ж.* — 1. бүки, бүкәй (балаларны куркыту өчен уйлап чыгарылган фантастик зат); 2. *перен.* *(угрюмый человек)* кеше сөймәс, караңгы чырайлы (ялгызлыкны яратучы, сүрән кеше).

**БУКА'ШКА** *ж. зоол.* — корт, кечкенә бөҗәк.

**БУ'КВА** *ж.* — 1. хәреф; 2. *перен.* формаль як; *соблюдать букву закона* — законны формаль яктан гына үтәү. ◇ **Буква в букву** — сүзгә сүз (мәсәлән, тәрҗемә). **Цепляться за букву** — хәрефкә ябышып яту.

**БУКВА'ЛЬНО** *нареч.* — 1. сүзгә сүз; һич үзгәртмичә; *перевести буквально* — сүзгә сүз тәрҗемә итү; *привести буквально что-нибудь слова* — кемнең дә булса сүзләрен һич үзгәртмичә китерү; 2. бөтенләй; һич тә; *у меня нет буквально ни одного свободного дня* — минем һич тә буш көнем юк.

**БУКВА'ЛЬНЫЙ** — 1. сүзгә сүз, хәрефкә хәреф; *буквальный перевод* — сүзгә сүз тәрҗемә; 2. туры, төгәл; *буквальное значение* — туры мәгънә, төгәл мәгънә.

**БУКВА'РНЫЙ** — әлифба... -ы; *букварный шрифт* — әлифба шрифты.

**БУКВА'РЬ** *м.* — әлифба, әлифба китабы.

**БУ'КВЕННЫЙ** — хәрефле, хәреф белән...; *буквенное обозначение* — хәрефле билгеләмә, хәреф белән билгеләлеш; *буквенное уравнение* — хәрефле тигезләмә.

**БУКВОЕ'Д** *м.*, **БУКВОЕ'ДКА** *ж. ирон.* хәрефкә ябышып ятучы, коры формалист.

**БУКВОЕ'ДСКИЙ** — формаль, формалистларча.

**БУКВОЕ'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *ирон.* — коры формализм, хәрефкә ябышып яту (чиктән тыш педантлык).

**БУКЕ'Т** *м.* — 1. букет, чәчәкләр бәйләме; 2. үзенә бер тәм, үзенә бер ис; *чай имеет букет* — чәйнең үзенә бер тәме бар (үзенә бер исе бар).

**БУ'КИ** *в знач. сказ. простореч. шутл.* — шикле, икеле; я булыр, я юк.

**БУКИНИ'СТ** *м.* — букинист (борынгы һәм сирәк очрый торган китаплар белән сату итүче).

**БУ'ККЕР** *м. с.-х.* — буккер (туфрак йомшарту коралы).

**БУКО'ЛИКА** *ж.* — буколика (көтүчеләр тормышын, авыл тормышын табигать чолганышында тасвир итә торган әдәбият).

**БУКОЛИ'ЧЕСКИЙ** — буколик; *буколическая поэзия* — буколик поэзия.

**БУ'КСА** *ж.* — букса (вагон күчәрен үз эчендә әйләндерә торган металл коробка).

**БУКСИ'Р** *м.* — буксир (1. баржаны яки салны тартып бара торган пароход; 2. буксир арканы, буксирга алу арканы; 3. *перен.* эштә артта калучыларга ярдәм).

**БУКСИ'РНЫЙ** — буксир... -ы; *буксирный пароход* — буксир пароходы.

**БУКСИРОВА'ТЬ** *несов.* — тартып алып бару (пароход баржаны).

**БУКСИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тартып алып барылу (баржа пароход тарафыннан).

**БУКСОВА'ТЬ** *несов.* — буксовать итү (бара алмыйча бер урында әйләнеп тору, мәсәлән, автомобиль көпчәге).

**БУЛАВА'** *ж.* — 1. чукмар, кистән; 2. *истор.* булава (электә власть символы).

**БУЛА'ВКА** *ж.* — булавка.

**БУЛА'ВОЧНИК** *м.* — 1. энә букчасы; 2. булавка остасы.

**БУЛА'ВОЧНЫЙ** — булавка... -ы; *булавочная головка* — булавка башы. ◇ **С булавочную головку** — энә очы кадәр генә; бик кечкенә, бик аз.

**БУЛА'НКА** *ж. обл.* — кола ат.

**БУЛА'НЫЙ** — кола (ат төсе).

**БУЛА'Т** *м.* — булат (1. бизәкле корыч; 2. *поэт. устар.* шундый корычтан ясалган кылыч, хәнҗәр).

**БУЛА'ТНЫЙ** — корыч...; *булатный меч* — корыч кылыч.

**БУ'ЛГАРЫ** (камские булгары) *истор.* — болгарлар, Кама болгарлары.

**БУЛГА'ЧИТЬ** *несов.* — болгату, җәнҗал чыгару, борчу, тынычсызлау, ыгы-зыгы куптару.

**БУ'ЛКА** *ж.* — булка, күмәч.

**БУ'ЛОЧНАЯ** *ж.* — булочный (икмәк кибете).

**БУ'ЛОЧНИК** *м.*, **БУ'ЛОЧНИЦА** *ж.* — 1. булка пешерүче; 2. булка сатучы, булочный хуҗасы.

**БУЛТЫ'Х** *межд.* — 1. гөмберт! *а он бултых в реку!* — ә ул елгага гөмберт! 2. чулт! *а он бултых камнем в реку* — ә ул чулт елгага таш белән! (чулт итеп бәрде, ыргытты).

**БУЛТЫХА'ТЬ** *несов.* — 1. *(взбалтывать)* болгату, чапылдату; 2. *(с шумом бросать)* чупылдатып ыргыту.

**БУЛТЫХА'ТЬСЯ** *несов.* — чапырдау, чапылдау (суда).

**БУЛТЫ'ХНУ'ТЬ** *сов.* — болгатып җибәрү, селкетеп җибәрү.

**БУЛТЫ'ХНУ'ТЬСЯ** *сов.* — чулт итеп төшү (суга).

**БУЛЫ'ЖНИК** *м.* — йомры таш.

**БУЛЫ'ЖНЫЙ** — таш җәелгән; *булыжное шоссе* — таш җәелгән юл.

**БУЛЬ-БУЛЬ** *межд.* — былт-былт (тар муенлы савыттан ага торган сыекча тавышы).

**БУЛЬВА'Р** *м.* — бульвар (киң аллея).

**БУЛЬДО'Г** *м.* — бульдог (1. кыска борынлы, зур башлы, карсак эт; 2. кыска көпшәле, эре калибрлы пулялы револьвер).

**БУЛЬДО'ЗЕР** *м. тех.* — бульдозер (1. табаклы һәм фасонлы калайны бөгү станогы; 2. *тех.* грунтны тигезләү һәм күчерү өчен тракторга алдан кертелә торган киң пычаксыман җайланма).

**БУ'ЛЬКАТЬ** *несов.* — былт-былт итү (тар муенлы савыттан сыекча агызганда).

**БУЛЬО'Н** *м.* — шулпа, ит шулпасы.

**БУЛЬО'ННЫЙ** — шулпа... -ы; *бульонное мясо* — шулпа ите.

**БУМА'ГА** I *ж.* — 1. *только ед.* кәгазь; 2. *офиц.* кәгазь, язу; *из центра пришла бумага* — үзәктән язу (кәгазь) килде; 3. *только мн.* документлар, кәгазьләр; *у него бумаги не в порядке* — аның документлары (кәгазьләре) тәртиптә түгел. ◇ **Остаться на бумаге** — кәгазьдә генә калу.

**БУМАГА** II *ж. мн.* нет, *текст.* — киҗе-мамык (мамык үзе һәм аннан тукылган тукымалар).

**БУМАГОМАРА'КА** *м. устар.* — к. бумагомаратель.

**БУМАГОМАРА'НИЕ** *ср. разг.* — кәгазь пычрату (кирәкмәс яки начар язу).

**БУМАГОМАРА'ТЕЛЬ** *м.*, **БУМАГОМАРА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. устар.* — кәгазь пычрату-

чы (начар, эчтәлексез әсәрләр, мәкаләләр язучы, булдыксыз язучы).

**БУМАГОПРЯДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — киҗе-мамык промышленносте.

**БУМАГОПРЯДИ'ЛЬНЫЙ** — киҗе-мамык эрләү... -ы; *бумагопрядильная машина* — киҗе-мамык эрләү машинасы.

**БУМАГОПРЯДИ'ЛЬНЯ** *ж.* — киҗе-мамык эрләү фабрикасы.

**БУМА'ЖКА** *ж.* — 1. кәгазь кисәге; 2. кәгазь акча. ◇ **Радужная бумажка** *дорев ол.* — йөз сумлык кәгазь акча.

**БУМА'ЖНИК** *м.* — бумажник (кәгазь акча һәм документлар салу өчен).

**БУМА'ЖНЫЙ** I — 1. кәгазь... -ы, кәгазь эшләп чыгара торган; *бумажное производство* — кәгазь производствосы; 2. кәгазь..., кәгазьдән ясалган; *бумажный фонарь* — кәгазь фонарь; 3. *перен.* кәгазьдә генә язылган (тормышка ашырылмый торган); *бумажные планы* — кәгазьдә генә язылган планнар. ◇ **Бумажная волокита** — кәгазь боткасы (эшне озакка сузу). **Бумажная душа, бумажный человек** — бюрократ.

**БУМА'ЖНЫЙ** II *текст.* — киҗе-мамык..., киҗе-мамыктан эшләнгән; *бумажная материя* — киҗе-мамык материя.

**БУМАЖО'НКА** *ж.* — кәгазь кисәге.

**БУМАЗЕ'ЙНЫЙ** *текст.* — 1. бумази... -ы, бумази эшләп чыгара торган; *бумазейное производство* — бумази производствосы; 2. бумази..., бумазидан тегелгән; *бумазейное платье* — бумази күлмәк.

**БУМАЗЕ'Я** *ж. мн.* нет — бумази.

**БУ'НКЕР** *м.* — бункер (1. мичләр янында күмер өчен ясалган чокыр; газогенераторлы машиналарда шакмак салына торган урын; 2. комбайнда сугылган ашлык җыелып бара торган урын; складта ашлык урыны).

**БУНКЕРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — бункерлау, бункерга салу.

**БУНКЕРО'ВЩИК** *м.* — бункерчы, бункерга тутыручы.

**БУНТ** I *м.* — бунт, баш күтәрү, гыйсьян.

**БУНТ** II *м.* — 1. бунт; кип, төргәк, бәйләм; 2. капчыклы товарлар өеме.

**БУНТА'РКА** *ж.* — к. бунтарь.

**БУНТА'РСКИЙ** — бунтарлык... -ы; гыйсьянчылык... -ы; *бунтарские речи* — бунтарьлык речьләре.

**БУНТА'РСТВО** *ср.* — бунтарьлык, фетнәчелек, гыйсьянчылык.

**БУНТА'РЬ** *м.* — бунт чыгаручы, бунтка котыртучы, фетнәче, гыйсьянчы.

**БУНТОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *(производить бунт)* бунт чыгару, бунт күтәрү; 2. *(подстрекать к бунту)* бунтка котырту, бунтка чакыру. 3. *перен.* котырыну, дулау.

**БУНТОВА'ТЬСЯ** *несов.* — бунт чыгару, бунт күтәрү.

**БУНТОВО'Й** — бәйләмле, киплы, пачкалы (товар).

**БУНТОВЩИ'К** *м.*, **БУНТОВЩИ'ЦА** *ж.* — бунт чыгаручы, бунт күтәрүче, фетнәче, гыйсьянчы.

**БУНЧУ'К** *м.* — бунчук (1. *истор.* гетманның, пашаның хакимлеге билгесе итеп гаскәрләрдә йөртелә торган бер башына ат койрыгы тагылган таяк; 2. полк оркестрында музыка коралы).

**БУРА'В** *м.* — борау.

**БУРА'ВИТЬ** *несов.* — бораулау, бораулап тишү.

**БУРА'ВИТЬСЯ** *несов. страд.* — бораулану, бораулап тишелү.

**БУРА'ВЧИК** *м.* — кечкенә борау, кадак боравы.

**БУРА'К** I *м. обл.* — кызыл чөгендер.

**БУРАК** II *м. обл.* — тырыс, туз тубал.

**БУРА'Н** *м.* — буран, кар бураны.

**БУРА'ННЫЙ** — буранлы.

**БУРА'Т** *м.* — кыл иләк (тегермәндә орлыкларны чистарту өчен).

**БУРАЧКИ'** *бот.* — тамчылы гөл.

**БУРА'ЧНИК** I *м.* — тырыс ясаучы.

**БУРА'ЧНИК** II *м. бот.* — кыяр үләне.

**БУРА'ЧНЫЙ** — кызыл чөгендер... -ы; *бурачный сок* — кызыл чөгендер суы.

**БУРБО'Н** *м. устар.* — тупас, надан кеше.

**БУРГОМИ'СТР** *м.* — бургомистр (Көнбатыш Европада шәһәр идарәсе башлыгы).

**БУРДА'** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. бурда, боламык (тәмсез болганчык эчемлек, тәмсез сыек аш); 2. *перен.* чуалчыклык, юк-бар сүз.

**БУРДЮ'К** *м.* — турсык (сыек әйберләр салу өчен хайван тиресеннән ясалган савыт).

**БУРДЮ'ЧНЫЙ** — турсык... -ы; *бурдючный кумыс* — турсык кымызы.

**БУРЕВЕ'СТНИК** *м.* — буревестник, давыл хәбәрчесе, диңгез акчарлагы (кош).

**БУРЕВО'Й** — давыл... -ы; *рыдай, буревая стихия!* — үкер, давыл стихиясе!

**БУРЕЛО'М** *м.* — 1. давыл аударган агачлар; 2. көчле җил-давыл.

**БУРЕ'ТЬ** *несов.* — көрәнләнү, көрән төскә керү.

**БУРЖУА'** *м. нескл.* — буржуа; буржуй, байгура.

**БУРЖУАЗИ'Я** *ж.* — буржуазия (капиталистик җәмгыятьтә җитештерү коралларына хуҗа булып торучы һәм ялланган эшчеләрне эксплуатацияләү хисабына яшәүче сыйныф).

**БУРЖУА'ЗНО-ДЕМОКРАТИ'ЧЕСКИЙ** — буржуаз-демократик.

**БУРЖУА'ЗНЫЙ** — буржуаз; *буржуазная печать* — буржуаз матбугат.

**БУРЖУ'ЙКА** *ж.* — 1. буржуй хатын-кыз; 2. *(времянка)* кечкенә тимер мич.

**БУРЖУ'ЙСКИЙ** — буржуй... -ы; буржуйларча...; *буржуйские выходки* — буржуй кыланышлары; буржуйларча кылану.

**БУРИ'ЛЬНЫЙ** — бораулау... -ы; *бурильная машина* — бораулау машинасы.

**БУРИ'ЛЬЩИК** *м.* — бораулаучы (эшче).

**БУРИ'ТЬ** *несов.* — бораулау, бораулап тишү (җирне, тау токымнарын).

**БУРИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — бораулану, бораулап тишелү.

**БУ'РКА** *ж.* — бурка (кавказлыларның җилкәгә салып йөри торган җинсез тула чикмәне).

**БУ'РКАТЬ** *несов.* — мыгырдау.

**БУ'РКНУТЬ** *сов.* — мыгырдап кую.

**БУРЛА'К** *м.* — бурлак (элекке заманда Волгада баржа тартучы).

**БУРЛА'ЦКИЙ** — бурлак... -ы; *бурлацкие песни* — бурлак җырлары.

**БУРЛА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — 1. бурлаклык; 2. *собир.* бурлаклар.

**БУРЛА'ЧИТЬ** *несов.* — бурлак булып йөрү, бурлак булып эшләү.

**БУРЛИ'ВЫЙ** — 1. ярсу(лы), шаулы, шаулап тора торган, кайнап тора торган; *бурливое море* — ярсу диңгез; 2. *перен.* ашкын, ярсу; *бурливое сердце* — ашкын күңел, ашкын йөрәк.

**БУРЛИ'ТЬ** *несов.* — *(о роднике)* ургылып чыгу; *(о кипящей воде)* быкырдап кайнау; *(о море)* ярсып дулкынлану; *(о чувствах)* ярсулану, ярсуланып тышка чыгу.

**БУРМИ'СТР** *м. истор.* — бурмистр (алпавытның крепостной крестьяннар өстеннән күзәтчелек итү өчен куйган старостасы).

**БУ'РНО** *нареч.* — 1. ярсып, ашкынып; 2. бик тиз; котырып.

**БУ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ярсулылык.

**БУ'РНЫЙ** — 1. давыллы, дулкынлы; *бурная осень* — давыллы көз; *бурное море* — дулкынлы диңгез; 2. кискен, ярсулы, омтылышлы, бик тиз; *бурный рост индустриализации* — индустриализациянең бик тиз үсүе; *бурные восторги* — ярсулы шатлыклар; 3. көчле; *бурные аплодисменты* — көчле кул чабулар.

**БУРОВА'Я** *сущ.* — буровой, бораулау скважинасы (нефть промышленностенда).

**БУРО'ВИТЬ** *несов. обл.* — 1. эләктерү, эз калдыру (хәрәкәт иткәндә); 2. ургылып чыгу (чишмә турында).

**БУРОВО'Й** — бораулау... -ы; *буровая скважина* — бораулау скважинасы.

**БУРОЗЁМ** *м.* — көрән туфрак.

**БУ'РСА** *ж. мн.* нет, *устар.* — бурса (иске заманда дини мәктәп, дини семинария, мәдрәсә).

**БУРСА'К** *м.* — бурсак (бурсада укучы).

**БУРСА'ЦКИЙ** — бурсак... -ы; *бурсацкие нравы* — бурсак гадәтләре.

**БУРТ** *м.* — бурт, өем.

**БУРУНДУ'К** *м. зоол.* — борындык (җәнлек).

**БУРЧА'ТЬ** *несов.* — 1. *(ворчать)* мыгырдау, мыгырдану; 2. *(о кипении)* быкырдау, быкырдап кайнау; 3. *(урчать)* чурлау, быкырдау (эч турында).

**БУ'РЫЙ** — көрән, коңгырт, коба.

**БУРЬЯ'Н** *м. мн.* нет — кура, каракура (эре чүп үлән).

**БУРЬЯ'НИСТЫЙ** — куралы; *бурьянистый корм* — куралы азык.

**БУ'РЯ** *ж.* — давыл, җил-давыл, буран, өермә, яңгырлы (карлы) көчле җил. ◇ Буря в стакане воды — бер дә юкка чәпчү (юк өчен, вак-төяк өчен дулау). Буря восторгов — чиксез шатлыклар.

**БУРЯ'Т** *м.* — бурят.

**БУРЯ'ТКА** *ж.* — бурят хатын-кызы.

**БУРЯ'ТСКИЙ** — бурят...-ы; *бурятский язык* — бурят теле.

**БУРЯ'ТЫ** *мн.* (*ед.* бурят) — бурятлар, бурят халкы.

**БУ'СИНА, БУ'СИНКА** *ж.* — энҗе бөртеге, сәйлән бөртеге, мәрҗән бөртеге.

**БУССО'ЛЬ** *ж. тех.* — буссоль (геодезиядә почмак үлчәгеч корал).

**БУ'СЫ** *мн.* — муенса (муенга тагу өчен зиннәт).

**БУТ** *м. мн.* нет — бут, ак таш (төзүгә китә торган таш).

**БУТАФО'Р** *м.* — бутафор, бутафория хәзерләүче.

**БУТАФО'РНЫЙ** — бутафория... -ы; *бутафорная мастерская* — бутафория мастерское.

**БУТАФО'РИЯ** *ж. мн.* нет — бутафория (1. уйналачак пьеса өчен кирәкле әйберләр; 2. *перен.* күз буяу өчен булдырылган ялган обстановка).

**БУТАФО'РСКИЙ** — 1. бутафория... -ы; *бутафорские принадлежности* — бутафория кирәк-яраклары; 2. *перен.* ялган; *бутафорский меч* — ялган кылыч.

**БУТЕРБРО'Д** *м.* — бутерброд (май, колбаса яки икра салынган икмәк телеме).

**БУТИ'ТЬ** *несов.* — бут салу.

**БУТИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — бут салыну.

**БУТО'Н** *м.* — чәчәк бөресе, чәчәк төймәсе.

**БУ'ТСЫ** *ед.* нет, *спорт.* — бутсы (футбол уйнаганда кию өчен махсус ботинка).

**БУТУ'З** *м. разг.* — юантык таза бала.

**БУТЫ'ЛКА** *ж.* — шешә, бутылка.

**БУТЫ'ЛОЧНЫЙ** — 1. шешә... -ы; *бутылочное стекло* — шешә пыяласы; 2. шешәле; *бутылочное пиво* — шешәле сыра.

**БУТЫ'ЛЬ** *ж.* — зур шешә.

**БУ'ФЕР** *м.* (*мн.* буферá) — буфер (1. каты бәрелүдән саклау өчен ике арага (мәсәлән, тимер юл вагоннары арасына) куела торган пружиналы диск; 2. *перен.* бәрелешүче (көрәшүче) ике як арасындагы группа яки дәүләт).

**БУ'ФЕРНЫЙ** — 1. буфер... -ы; *буферный диск* — буфер дискы (тәлинкәсе); 2. буфер...; *буферное государство* — буфер дәүләт.

**БУФЕ'Т** *м.* — буфет (1. ашау-эчү әйберләре сатыла торган өстәл яки бүлмә; 2. савыт-саба шкафы).

**БУФЕ'ТНЫЙ** — буфет... -ы; *буфетная цена* — буфет бәясе.

**БУФЕ'ТЧИК** *м.* — буфетчик, буфетта эшләүче.

**БУФЕ'ТЧИЦА** *ж.* — буфетчица, буфетта эшләүче хатын-кыз.

**БУФФ** *в знач. неизм. прилаг.* — кызыклы, көлке, мәзәк.

**БУФ(Ф)О'Н** *м.* — 1. буффон (үтә көлке, мәзәк рольләрне башкаручы актёр); 2. *перен.* шаян, мәзәкче кеше.

**БУФ(Ф)ОНА'ДА** *ж.* — **1.** буффонада (үтә көлке театр уены); **2.** *перен.* урынсыз, тупас шаянлык.

**БУФФО'НИТЬ** *несов.* — шаяру, шамакайлану, кылану.

**БУХ** *звукоподраж.* — гөмберт! гөрс! чулт! (итеп суга төшү, егылу), шап! дөп! (итеп сугу).

**БУ'ХАТЬ** *несов.* — 1. шап иттереп сугу; *бухать топором* — балта белән шап иттереп сугу; **2.** *(шумно ронять)* гөрс иттереп төшерү; аудару; **3.** гөрселдәү; гөрелдәү; *бухали пушки* — пушкалар гөрселди иде; **4.** *перен. (необдуманно говорить)* кирәкмәгәнне сөйләү, ярамаганны сөйләү.

**БУ'ХАТЬСЯ** *несов.* — гөрселдәп аву, егылу, дөп итеп төшү.

**БУХГА'ЛТЕР** *м.* — бухгалтер.

**БУХГАЛТЕ'РИЯ** *ж. мн.* нет — бухгалтерия. ◇ **Двойная бухгалтерия** *перен.* — эштә икейөзлелек, ялган хәрәкәт.

**БУХГА'ЛТЕРСКИЙ** — **1.** бухгалтер ... -ы; *бухгалтерская должность* — бухгалтер вазифасы; **2.** бухгалтерия... -ы; *бухгалтерский счёт* — бухгалтерия счёты.

**БУ'ХНУТЬ** I *сов.* — **1.** шап иттереп сугып җибәрү; **2.** гөрс иттереп төшереп җибәрү, ауларып җибәрү; **3.** гөрселдәтеп атып җибәрү; **4.** *(необдуманно сказать)* әйтеп ташлау, ычкындырып җибәрү.

**БУ'ХНУТЬ** II *несов.* — бүртү, күбенү.

**БУ'ХНУТЬСЯ** *сов.* — гөрселдәп авып китү, егылып китү, дөп итеп төшеп китү.

**БУ'ХТА** I *ж.* — бухта, кечкенә култык (диңгездә).

**БУ'ХТА** II *ж.* — бухта (түгәрәкләндереп төргән аркан төргәге).

**БУ'ХТЫ-БАРА'ХТЫ**: с бухты-барахты — тик-томалга, уйлап-нитеп тормастан, аннан-моннан гына (эшләү).

**БУ'ЦЫ** — к. бутсы.

**БУ'ЧА** *ж. мн.* нет — шау-шу, ыгы-зыгы, тавыш, талаш, ызгыш, гауга.

**БУ'ЧИТЬ** *несов.* — **1.** селтедә кайнату (мәсәлән, керне); **2.** йомшарту (тиреде иләү алдыннан махсус эретмәләргә салып).

**БУ'ЧИТЬСЯ** *несов. страд.* — **1.** селтедә кайнатылу; **2.** йомшартылу (тире турында).

**БУШЕВА'ТЬ** *несов.* — **1.** давыллану, дулкынлану, котырыну; *море бушует* — диңгез котырына; **2.** *перен.* дуамаллану, котырыну, дулау, ду килү, ярсу. ◇ **Бушует кровь** — кан кайный. **Бушует радость** — шатлык ташый.

**БУШЛА'Т** *м.* — бушлат (матрослар өчен махсус куртка).

**БУШМЕ'НЫ** *мн.* (*ед.* бушмен) — бушменнар, бушмен халкы (Көньяк Африкада).

**БУШМЕ'НСКИЙ** — бушмен... -ы, бушменнар... -ы; *бушменский язык* — бушмен теле.

**БУЯ'Н** I *м.* — дуамал, дачы, сугыш чукмары, бәйләнчек, җәнҗалчы, дау кубаручы.

**БУЯ'Н** II *м. устар.* — пристаньнарда товар өю урыны.

**БУЯ'НИТЬ** *несов.* — җәнҗал чыгару, ду куптару, гауга чыгару.

**БУЯ'НСТВО** *ср.* — җәнҗал чыгару, ду куптару.

**БЫ** *частица* — **1.** ... -ган булыр иде; *он бы пришёл (он пришёл бы), если бы был здоров* — әгәр дә сәламәт булса, ул килгән булыр иде; *мне бы не справиться, если бы ты не помог* — әгәр дә син булышмаган булсаң, мин җиңә алмаган булыр идем; **2.** ... -п алыр идең, ... -п алсын иде; *ты бы соснул немножко* — син бераз йоклап алыр идең; *он бы соснул немножко* — ул бераз йоклап алсын иде; **3.** ... -сы иде; *соснуть бы немножко* — бераз йоклап аласы иде. ◇ **Если бы** — әгәр дә.

**БЫВА'ЛО** *ввод. сл.* — **1.** бервакытлар, кайчандыр, ... -ган чаклар бар иде; *бывало, мы с ним ходили в лес* — бервакытлар без аның белән урманга йөри торган идек; *в молодости, бывало, мы с ним охотились на зайцев* — яшьлектә безнең аның белән куян аулаган чаклар бар иде; кайчандыр яшьлектә без аның белән куян аулый торган идек; **2.** электә ... -а торган иде(к); *он возьмёт, бывало, ружьё и отправится на охоту* — электә ул мылтыгын ала да ауга китә торган иде. ◇ **Как ни в чём не бывало** — бернәрсә дә булмаган шикелле; *вчера очень нездоровилось, а сегодня встал, как ни в чём не бывало* — кичә кәефем бик начар иде, ә бүген бернәрсә дә булмаган шикелле тордым. **Как не бывало** — бетте, югалды, эзе дә калмады, су сипкәндәй булды; *боли как не бывало* — авырту бетте (су сипкәндәй булды).

**БЫВА'ЛЫЙ** — **1.** *(много видавший)* дөнья күргән, күпне күргән, тәҗрибәле, шомарган; **2.** *(не новый)* электә булган, булган, күнегелгән.

**БЫВА'ЛЬЩИНА** *ж.* — күргән-белгәннәр, күргән-булганнар (баштан узган, булып үткән вакыйга турында хикәя).

**БЫВА'ТЬ** *несов.* — **1.** булу; *таких вещей не бывает* — мондый хәлләр булмый; *вечером я всегда бываю дома* — кич белән мин һәрвакыт өйдә булам; **2.** булгалау; *бывают странные сны* — гаҗәп төшләр булгалый.

**БЫ'ВШИЙ** — **1.** булган; *вещи, бывшие в употреблении* — кулланылуда булган әйберләр; **2.** элекке; *гараж расположен в помещении бывшего манежа* — гараж элекке манеж бинасында урнашкан. ◇ **Бывшие люди** — **1.** кешелеген югалткан кешеләр; **2.** электә эксплуататор булган, революциядән соң өстенлекләрен югалткан кешеләр.

**БЫ'ДЛО** *ср. обл. бран.* — хайван, ангыра, булдыксыз, юаш.

**БЫК** *м. зоол.* — үгез. ◇ **Упёрся, как бык** — үзенекен итә, киреләнә. **Смотреть быком** — сөмсез карау, маңгай астыннан карау.

**БЫКИ'** *мн.* — күпер баганалары.

**БЫЛЕВО'Й** — к. былинный.

**БЫ'ЛИЕ** *ср. мн.* нет, *устар.* — үлән, чирәм.

**БЫЛИ'НА** I *ж.* — былина (легендар батырлар турында рус халык эпосы).

**БЫЛИ'НА** II *ж. бот.* — үлән сабагы.

**БЫЛИ'ННЫЙ** — былина... -ы; эпик; *былинный сюжет* — былина сюжеты.

**БЫЛИ'НЩИК** *м.* — былина сөйләүче.

**БЫ'ЛО** — иде (м. к); *написал было, но не послал* — язган идем, ләкин җибәрмәдем; *собрались было, но не пошли* — җыенган идек, ләкин бармадык. ◇ **Едва было, чуть было** — чак кына.

**БЫЛО'Е** *сущ.* — үткәндәгеләр, булып үткәннәр, баштан узганнар; күргән-белгәннәр; *всё здесь напоминает мне былое* — монда барысы да миңа үткәндәгеләрне искә төшерә.

**БЫЛО'Й** — булган, үткән, элекке, борынгы, әүвәлге.

**БЫЛЬ** *ж.* — **1.** баштан узган вакыйга, булган вакыйга; **2.** булган вакыйга турында хикәя.

**БЫЛЬЁ** *ср. устар.*: **быльём поросло** — онытылган, күптән булып онытылган.

**БЫСТРИНА'** *ж.* — ургыл, каты агым (елганың бик каты ага торган урыны).

**БЫ'СТРО** *нареч.* — тиз-тиз генә, шәп, җәһәт.

**БЫСТРОГЛА'ЗЫЙ** — елгыр күзле, йөгерек күзле.

**БЫСТРОКРЫ'ЛЫЙ** — тиз очышлы, тиз оча торган.

**БЫСТРОНО'ГИЙ** — җитез йөрешле, йөгерек, тиз йөрүчән.

**БЫСТРОТА'** *ж. мн.* нет — тизлек; җитезлек; кызулык. ◇ **Быстрота ума** — зирәклек, тиз төшенүчәнлек.

**БЫСТРОТЕКУ'ЩИЙ** — алкын, тиз агышлы, тиз агымлы.

**БЫСТРОТЕ'ЧНЫЙ** — тиз үтешле.

**БЫСТРОХО'ДНЫЙ** — тиз йөрешле.

**БЫ'СТРЫЙ** — **1.** тиз, кызу, шәп; **2.** *перен.* булдыклы, җитез, елгыр.

**БЫТ** *м. мн.* нет — тормыш, көнкүреш, көндәлек тормыш.

**БЫТИЕ'** *ср. мн.* нет — **1.** яшәеш, барлык; **2.** *филос.* объектив чынбарлык.

**БЫ'ТНОСТЬ** *ж.*: **в бытность** — булган вакытта, булган чагында; *в бытность мою студентом* — мин студент булган вакытта; *в бытность его на юге* — ул көньякта булган чагында.

**БЫТОВА'ТЬ** *несов.* — яшәү, яшәп килү, булу, булып тору.

**БЫТОВИ'К** *м.* — тормыш, көнкүреш мәсьәләләре турында язучы.

**БЫТОВО'Й** — **1.** тормыш... -ы, көнкүреш... -ы; *бытовые условия* — тормыш (көнкүреш) шартлары; **2.** көнкүреш мәсьәләләрен чагылдыра торган; *бытовая драма* — көнкүреш мәсьәләләрен чагылдыра торган драма.

**БЫТОПИСА'НИЕ** *ср. устар.* — тормыш, көнкүреш тарихы (тормышны, көнкүрешне тарихи яктан чагылдырып язу).

**БЫТОПИСА'ТЕЛЬ** *м.* — тормыш, көнкүреш темаларына язучы.

**БЫТЬ** — **1.** булу, бар булу (рус телендә *быть* фигыленең хәзерге заман төрләреннән *есть* формасы, сирәк кулланыла торган *суть* формасы, *будучи* формасы гына бар; үткән заман *был, была, было, были* формалары татарча *идем, идең, иде, идек, идегез, иделәр* яки *булдым, булдың, булды, булдык, булдыгыз, булдылар* яки *бар иде* фигыльләренә туры киләләр, мәсәлән, *я был рабочим* — мин эшче идем; *я был в Киеве* — мин Киевта булдым; *у него был сын* — аның улы бар иде; киләчәк заман *буду, будешь, будет, будем, будете, будут* формалары үзләре генә кулланылганда *булырмын, булырсың, булыр, булырбыз, булырсыз, булырлар* формаларына туры киләләр, мәсәлән, *будет дождь* — яңгыр булыр; инфинитив формасында куелган төп фигыль алдында килсәләр, ул фигыльдән киләчәк заманның кушма формасын ясыйлар, мәсәлән, *будешь писать* — язарсың; *будем играть* — уйнарбыз); **2.** килү, килеп җитү; *он и сам скоро будет* — ул үзе дә тиздән килер. ◇ **Быть может, может быть** — бәлки, ихтимал. **Была не была!** — булмаса булган икән (тәвәккәлләп, сынап карарга кирәк)! **Будь, что будет** — ни булса булыр (тәвәккәлләп карарга кирәк). **Не может быть** — булмас, мөмкин түгел. **Должно быть** — ... -дыр ахры; *должно быть, он не придёт* — ул килмәстер ахры. **Так и быть** — әйдә ярар инде, булса булсын. **Был таков, была такова** — китеп тә барды, сызды, шылды, тайды, җилләр исте; *сыр выпал — с ним была плутовка такова* — сыр төшеп китте — хәйләкәр (төлке) аны эләктереп китеп тә барды (сызды). **Не тут-то было** — (көткәне) барып чыкмады; *приехал я в деревню, думал распишусь. Не тут-то было* — мин авылга килдем, язылышырмын (өйләнермен) дип уйладым. (Көткәнем) барып чыкмады. **Будь добр, будь любезен, будьте добры** — рәхим итеп... -чы, зинһар, зинһар өчен; *будьте добры, перепишите это* — рәхим итеп шушыны күчереп языгызчы. **Не я буду, я не я буду** — исемем ... булмасын; *не я буду, если это забуду* — әгәр дә моны онытсам, исемем ... (Абдул)булмасын. **Стало быть** — димәк, шулай булгач. **Будь то** — кирәк алар (ул)... булсын; *Советская Армия никогда не будет воевать против всего народа, будь то поляки, англичане, румыны или французы* — кирәк алар поляклар, кирәк англичаннар, кирәк румыннар яки французлар булсыннар, Совет Армиясе һичкайчан барлык халыкка каршы сугышмаячак. **Надо быть** *просторeч.* — к. быть может. **Быть за одно** — бер сүздә булу. **Как быть** — ни эшләргә. **Будет тебе, будет с тебя** — җитәр сиңа. **Между нами будь сказано** — әйткән җирдә калсын.

**БЫТЬЁ** *ср. мн.* нет, *устар.* — көнкүреш, тормыш.

**БЫЧА'ТИНА** *ж.* — үгез ите.

**БЫЧА'ЧИЙ, БЫ'ЧИЙ** — үгез... -ы; *бычья кожа* — үгез тиресе.

**БЫЧИ'НА** *ж.* — ике яшьтән узган үгез тиресе.

**БЫЧИ'ТЬСЯ** *несов. просторeч.* — **1.** чырай карангылану; **2.** *(упрямиться)* киреләнү.

**БЫЧКОВА'ТЫЙ** — карангы чырайлы, маңгай астыннан караучы.

**БЫЧО'К** I *м.* — яшь үгез, үгез бозау. ◇ **Пить бычком** — тын алмыйча эчү.

**БЫЧО'К** II *м.* — бычок, маймыч (вак балык).

**БЭ** *ср. нескл.* — би (б хәрефенең исеме). ◇ **Ни бэ, ни мэ (не знать)** — бернәрсә дә белмәү; *он ни бэ, ни мэ в математике* — ул математикадан бернәрсә дә белми.

**БЮВА'Р** *м.* — бювар (киптергеч кәгазьләр салынган дәфтәр яки папка).

**БЮВА'РНЫЙ** — бювар... -ы; *бюварная бумага* — бювар кәгазе.

**БЮДЖЕ'Т** *м.* — **1.** бюджет (а. дәүләтнең билгеле бер вакыт эчендә җыярга һәм тотарга чамаланган керем-чыгым исәбе; б. аерым кешенең яки семьяның керем-чыгымы); **2.** исәп-хисап; *бюджет времени* — вакытның исәп-хисабы. ◇ **Выходить из бюджета** — чамадан тыш расходлану, расход тоту.

**БЮДЖЕ'ТНЫЙ** — бюджет... -ы; *бюджетный год* — бюджет елы.

**БЮЛЛЕТЕ'НЬ** *м.* — бюллетень (**1.** кыска рәсми хәбәр, белдерү, мәсәлән, авыруның барышы турында; **2.** учреждениеләрнең, гыйльми җәмгыятьләрнең вакытлы матбугаты; **3.** яшерен тавыш белән сайланырга күрсәтелгән кандидатның исеме, фамилиясе язылган кәгазь; **4.** билгеле бер темага багышланган стена газетасы; **5.** *просторечн.* больничный листок).

**БЮ'РГЕР** *м.*—**1.** бюргер (шәһәрдә яшәүче, шәһәр кешесе); **2.** *перен. ирон.* мещан, обыватель.

**БЮРО'** *ср. нескл.* — бюро (**1.** сайланып куелган җитәкче орган; **2.** учреждениедә билгеле бер эшнең башында тора торган орган; **3.** кайбер учреждениеләр, конторалар өчен кабул ителгән исем; *справочное бюро* — белешмәләр бюросы; **4.** канцелярия өстәленең бер төре, конторка).

**БЮРОКРА'Т** *м. неодобр.* — бюрократ, формалист.

**БЮРОКРАТИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— бюрократлаштыру.

**БЮРОКРАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — бюрократизм, бюрократлык.

**БЮРОКРАТИ'ЧЕСКИ** *нареч.*— бюрократларча.

**БЮРОКРАТИ'ЧЕСКИЙ** — бюрократларча..., бюрократлык... -ы; *бюрократическое отношение к делу* — эшкә бюрократларча карау.

**БЮРОКРА'ТИЯ** *ж. мн.* нет — бюрократия (**1.** буржуаз дәүләтләрдә: массадан аерылган һәм эксплуататор сыйныфлар интересларын яклаучы чиновниклар администрациясе тарафыннан алып барыла торган идарә системасы; **2.** *собир.* шундый системадагы идарә кешеләре, бюрократлар; **3.** *разг. фам.* эшкә зарарлы булуына карамастан, формальлекләр, канцелярия шартлары турында чиктән тыш кайгырту).

**БЮСТ** *м.* — бюст (**1.** кеше гәүдәсенең билдән югары өлешенең скульптурасы; **2.** кеше тәненең билгә кадәр булган өске өлеше).

**БЮСТГА'ЛЬТЕР** *м.* — бюстгальтер, лифчик.

**БЯ'ЗЕВЫЙ** — бәз..., бүз...; бәздән тегелгән; *бязевая рубашка* — бәз күлмәк.

**БЯЗЬ** *ж. мн.* нет, *текст.* — бәз, бүз (мамык тукыма).

**БЯ'КА** *ж.* — әәй, начар, пычрак (балалар телендә).

**БЯ'ША** *межд.* — бәрә-бәрә, бәрәч-бәрәч (бәрән яки сарык чакыру ымлыгы).

**БЯ'ШКА** I *ж.* — к. бяка.

**БЯ'ШКА** II *ж. обл.* — **1.** сарык (балалар телендә); **2.** бәрәч; *бяшка-бяшка!* — бәрәч-бәрәч!

# В

**В** I *предлог с вин. п.* — **1.** *(на вопросы „куда?“, „во что?“)*... -га; ... эченә; *идём в школу* — мәктәпкә барабыз; *положи в чемодан* — чемоданга сал, чемодан эченә сал; *превратить в пар* — парга әйләндерү; **2.** *(на вопрос „когда?“ при определении дня)*... көн(не); *в субботу* — шимбә көн (не); **3.** *(на вопрос „когда?“ при определении часа)*... -да; *в десять часов* — сәгать унда (яки: ун сәгатьтә); **4.** *(на вопрос „сколько раз в год?“)*... -га; *дважды в год* — елга ике тапкыр; **5.** *(в течение какого-л. времени)*... -да, ... эчендә; *в три дня* — өч көндә, өч көн эчендә; **6.** *(при указании размера, веса, цены* и т. п.)... авырлыктагы; *груз весом в одну тонну* — бер тонна авырлыгындагы йөк; **7.** *(при обозначении кратности)*... тапкыр; *в пять раз больше* — биш тапкыр зуррак; **8.** *(только мн., для обозначения вступления в какую-н. профессию, должность, положение)*... -лыкка; *поступить в дворники* — дворниклыкка керү; *быть избранным в депутаты* — депутатлыкка сайлану; **9.** *(при обозначении игры) играть в футбол* — футбол уйнау. ◇ **Мальчик весь в отца** — малай нәкъ әтисе; малай нәкъ әтисенә охшаган; малай нәкъ әтисе, суйган да каплаган. **Комната в десять квадратных метров** — ун квадрат метрлы бүлмә. **Смотреть в окно** — тәрәзәдән карау. **В знак дружбы** — дуслык йөзеннән, дуслык хөрмәтенә. **Во исполнение постановления ...** — ... карарын үтәү йөзеннән.

**В** II *предлог с предл. п.* — **1.** *(на вопросы „где?“, в чём?)*... -да; ... эчендә; *в школе* — мәктәптә; *в столе* — өстәл эчендә, өстәл тартмасында; **2.** *(на вопрос „когда?“*

*в сочетании с названиями месяцев или с порядковыми обозначениями века, года, часа)*... -да; *в сентябре* — сентябрьдә; *в пятом году* — бишенче елда; *в двадцатом веке* — егерменче йөздә (гасырда); *в пятом часу* — бишенче сәгатьтә; 3. *(при указании, из скольких частей состоит что-н. целое)*... -лы; *драма в пяти действиях* — биш пәрдәле драма; *словарь в четырёх томах* — дүрт томлы сүзлек; 4. *(при указании, как и из чего что-н. сделано)*... белән ... -ган; *драма в стихах* — шигырь белән язылган драма; *рисунок в красках* — буяу белән ясалган рәсем; 5. *(при указании подробностей костюма)*... -дан; *он был в летнем костюме* — ул җәйге костюмнан иде; 6. *(о пребывании кого-н. кем-н.)*... булып,... -лыкта; *мой отец служил в дворниках* — минем әтием дворник булып эшләгән; 7. *(для обозначения порядка перечисления в сочетании с порядковыми числит. во мн. ч.)*... -дан, ... -лай; *в-третьих* — өченчедән, өченчеләй; 8. *(в каком расстоянии?)*... -да; *в двух километрах от города* — шәһәрдән ике километрда. ◇ **Остаться в дураках** — алдану, төпсез чанага утыру. **Усы в колечках** — бөтерелгән мыек. **Недостаток в овощах** — яшелчәләрнең җитешмәве. **Вычислить в процентах** — процентлар белән исәпләп чыгару. **В случае, если...** — әгәр... -са, әгәр... -а калса; *в случае, если он придёт...* — әгәр ул килсә, әгәр ул килә калса... **В том числе** — шул исәптән. **В качестве...** — ... булып, ... итеп, ... сыйфатында. **В конце концов** — ахыр чиктә, ниһаять.

**ВА-Б'АНК** *нареч.* — ва-банк („уендагы бөтен акчага барам, сугам" мәгънәсендә карта уенында кулланыла). ◇ **Идти ва-банк** — тәвәккәллеккә бару, ни булса булыр дип тәвәккәллек итү, икенең берсе булыр дип эшләү.

**ВА'БИК** *м. охот.* — вабик, сыбызгы (ауда кошларны, җәнлекләрне алдап чакыру өчен).

**ВА'БИЛЬЩИК** *м. охот.* — вабикчы (кошларны, җәнлекләрне вабик белән алдап чакыручы аучы).

**ВА'БИТЬ** *несов. охот.* — вабик белән чакыру.

**ВАВИЛО'НСКОЕ СТОЛПОТВОРЕ'НИЕ** — *перен.* мәгънәсезгә шаулашу, бик зур тәртипсезлек, чамасыз ыгы-зыгы, бик зур шау-шу, бик зур чуалчыклык.

**ВАГО'Н** *м.* — 1. вагон; 2. *перен.* бик күп, хисапсыз, бер йөк, бер олау; *книг у него вагон* — аның китаплары бик күп.

**ВАГОНЕ'ТКА** *ж. тех.* — вагонетка (йөк ташу өчен кулланыла торган кечкенә вагон).

**ВАГО'ННЫЙ** — вагон... -ы; *вагонная ось* — вагон күчәре.

**ВАГОНОВОЖА'ТЫЙ** *м.* — вагоновожатый, трамвай йөртүче.

**ВАГОНОРЕМО'НТНЫЙ** — вагоннарны ремонтлау... -ы; вагоннарга ремонт ясау... -ы; *вагоноремонтные мастерские* — вагоннарны ремонтлау мастерскойлары.

**ВАГОНОСТРОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — вагоннар ясау.

**ВАГОНОСТРОИ'ТЕЛЬНЫЙ** — вагоннар ясау... -ы, вагоннар ясый торган; *вагоностроительный завод* — вагоннар ясау заводы, вагоннар ясый торган завод.

**ВАГРА'НКА** *ж. тех.* — вагранка (чуен һәм төсле металлар эретә торган кечкенә мич).

**ВАГРА'НЩИК** *м.* — вагранщик (вагранкада эшләүче).

**ВА'ЖИВАТЬ** I *несов. многокр. разг.* — житәкләп йөрткәләү; уенда житәкчелек итү.

**ВА'ЖИВАТЬ** II *несов. разг.* — ташыштыргалау.

**ВА'ЖНИЧАТЬ** *несов.* — 1. *(напускать на себя важность)* эреләнү, эре тоту, эре кылану, үзен зурга санау, үзен зурга кую; 2. *(воображать о себе)* әллә кем булу, әллә кем булып йөрү; 3. *(кичиться)* масаю, борын күтәрү, кәпрәю, тәкәбберләнү, кукраю.

**ВА'ЖНО** — 1. *нареч. (воображая о себе)* эреләнеп, масаеп, тәккәберләнеп, әллә кем булып, эре генә; 2. *нареч. (гордо)* горур рәвештә, маһабәт рәвештә, олысымак, үзен эре тотып; 3. *в знач. сказ.* мөһим, әһәмиятле, бик кирәкле, зарур.

**ВА'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(значительность)* әһәмиятлелек, мөһимлек; 2. *(горделивый вид)* тәкәббер кыяфәт, эре кыяфәт, эрелек. ◇ **Эка важность или велика важность** — исең киткән икән, искитәрлек урын юк.

**ВА'ЖНЫЙ** — 1. *(значительный)* мөһим, әһәмиятле, кирәкле; 2. зур, зур дәрәҗәле; *важный человек* — зур кеше, зур дәрәҗәле кеше; 3. *(горделивый)* эре, тәкәббер; 4. *простореч.* яхшы; *сукно важное* — сукносы яхшы. ◇ **Говорить о важных материях** *ирон.* — конкрет булмаган әйберләр турында сүз алып бару.

**ВА'ЗА** *ж.* — ваза.

**ВАЗЕЛИ'Н** *м. мн.* нет — вазелин.

**ВАЗЕЛИ'НОВЫЙ** — 1. вазелин... -ы; *вазелиновое производство* — вазелин производствосы; 2. вазелинлы; *вазелиновое мыло* — вазелинлы сабын.

**ВАКА'НСИЯ** *ж.* — вакансия, буш урын (учреждение штатындагы, уку йортындагы буш урын).

**ВАКА'НТНЫЙ: вакантное место** — буш урын (штатта).

**ВАКАЦИО'ННЫЙ** *устар.* — вакация... -ы, каникул... -ы; *вакационные месяцы* — вакация айлары.

**ВАКА'ЦИЯ** *ж.* — вакация, каникул.

**ВА'КСА** *ж. мн.* нет — вакса.

**ВА'КСИТЬ** *несов.* — ваксалау, вакса белән чистарту, вакса белән ялтырату.

**ВА'КСИТЬСЯ** *несов. страд.* — вакса белән чистартылу, вакса белән ялтыратылу.

**ВАКХАНА'ЛИЯ** *ж.* — 1. *чаще мн. истор.* вакханалия (борынгы Римда һәм Грециядә аракы алласы Вакх хөрмәтенә бәйрәм); 2. *(оргия)* гадәттән тыш эчкечелек,

фәхеш, бозыклык; 3. *перен.* чиктән тыш тәртипсезлек.

**ВАКХА'НКА** *ж. перен.*—оятсыз хатын, фахишә.

**ВАКХИ'ЧЕСКИЙ** — шашыну дәрәҗәсендә дәртле.

**ВАКЦИ'НА** *ж. мед.* — вакцина (йогышлы авыруларга каршы прививка ясау өчен кулланыла торган препарат).

**ВАКЦИНА'ЦИЯ** *ж.* — вакцинация (берәр авырудан саклану өчен вакцина белән прививка ясау).

**ВАЛ** I *м.* — зур дулкын.

**ВАЛ** II *м.* — вал (дошманнан саклану яки хуҗалык максатлары өчен туфрактан өелгән ныгытма).

**ВАЛ** III *м. тех.* — вал (төрле машиналарда һәм механизмнарда).

**ВАЛА'НДАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. *(бездельничать)* эшсез йөрү, эшләмичә тик йөрү, тырай тибү; 2. *(долго возиться)* озак маташу, акрын кайнашу; 3. *(пачкаться)* пычрану.

**ВАЛЕ'ЖНИК** *м. собир.* — чыбык-чабык, коры-сары (корып сынып төшкән ботаклар, агачлар).

**ВАЛЁК** *м.* — 1. *(бельевой)* бәләк, тукмак; 2. *(в экипаже)* постромка агачы, вәлүк; 3. *тип.* валёк.

**ВА'ЛЕНКИ** *мн.* (*ед.* валенок) — киез итек.

**ВА'ЛЕНЫЙ** — басылган, йоннан басып эшләнгән.

**ВАЛЕРИА'НА, ВАЛЕРЬЯ'НА** *ж. бот.* — валериан, песи үләне.

**ВАЛЕРЬЯ'НКА** *ж. мед.* — валерьянка, валериан тамчылары (дару).

**ВАЛЕРЬЯ'НОВЫЙ** — валериан... -ы, песи үләне... -ы; *валерьяновый корень* — валериан тамыры, песи үләне тамыры.

**ВА'ЛИК** *м.* — 1. *тех.* валик, кечкенә вал; 2. *(диванный)* валик (диванның ике башына куела торган, тыгыз итеп тутырылган озынча түгәрәк мендәр).

**ВАЛИ'ТЬ** I *несов.* — 1. *(опрокидывать)* аудару, егу; 2. *(в кучу)* өю, тутыру, төяү (тәртипсез рәвештә); 3. аудару, сылтау; *валить вину на чужого* — гаепне кешегә аудару (сылтау).

**ВАЛИ'ТЬ** II *несов.* — 1. агылу, агылып килү; *народ так и валит* — халык агыла да агыла, халык агылып килә; 2. *(подыматься, падать во множестве)* ишелеп яву (кар); ургылып чыгу (төтен); 3. *пов. накл.* **вали, валите** — әйдә! эшли бир! йөри бир! китә бир!

**ВАЛИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *(падать)* аву, егылу, коелу; 2. янтаю, кырынаю; *диван валится на бок* — диван бер якка янтая; 3. *(разрушаться)* ишелү, җимерелү; 4. *(умирать во множестве)* кырылу, күпләп үлү. ◇ **Валится из рук** — кул бармый, эшлисе килми.

**ВА'ЛКИЙ** — кырынаючан, кыйшаючан, янтаючан, тотрыксыз. ◇ **Ни шатко, ни валко** — уртача, бертөрле, беркөе, гадәти генә. **Валкая походка** — алпан-тилпән йөрү.

**ВАЛОВО'Й** — барлык, тулай, гомуми; *валовой доход* — барлык керем.

**ВАЛО'М** *нареч.*: **валом валить** — агылып килү, өерелеп килү, ябырылып килү, күпләп килү.

**ВАЛОРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — валоризация (1. товарның бәясен ясалма рәвештә күтәрү өчен эшләнгән чаралар; 2. кәгазь акчаның курсын күтәрү өчен эшләнгән чаралар).

**ВАЛТО'РНА** *ж. муз.*— валторна (музыка коралы).

**ВАЛТОРНИ'СТ** *м.*— валторнист, валторначы, валторнада уйнаучы.

**ВАЛУ'Н** *м.* — валун (зур йомры таш).

**ВАЛУ'Х** *м.*— печкән тәкә.

**ВАЛЬВА'ЦИЯ** *ж.*— вальвация (теге яки бу дәүләтнең акча берәмлегенә күчереп, чит ил акчасының кыйммәтен билгеләү).

**ВА'ЛЬДШНЕП** *м. зоол.*— урман кулигы, тәллэтәвеч (кош).

**ВАЛЬС** *м. муз.*— вальс (1. бию; 2. көй).

**ВАЛЬСИ'РОВАТЬ** *несов.*— вальс бию.

**ВАЛЬЦЕВА'ТЬ, ВАЛЬЦОВА'ТЬ** *несов.*— вальцовать итү, вальцовкалау (ике вал арасыннан сыттырып уздыру).

**ВАЛЬЦОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— вальцовать ителү, вальцовкалану.

**ВАЛЬЦО'ВКА** *ж. тех.*— 1. *только ед.* к. вальцовать; 2. *(машина)* вальцовка.

**ВАЛЬЦО'ВОЧНЫЙ** — валцовкалау... -ы; *вальцовочный процесс*—вальцовкалау процессы.

**ВАЛЬЦО'ВЩИК** *м.*, **ВАЛЬЦО'ВЩИЦА** *ж.* — вальцовщик, вальцовкалаучы (эшче).

**ВА'ЛЬЩИК** *м.*— егучы, аударучы (урман кисkәндә агач егучы эшче).

**ВАЛЬЯ'ЖНЫЙ** — нәфис, гүзәл; матур эшләнгән.

**ВАЛЮ'ТА** *ж. мн.* нет, *экон.*— валюта (1. дәүләтнең акча берәмлеге, мәсәлән, сум, франк, доллар; 2. чит ил акчасы; 3. вексельдә күрсәтелгән түләү сумасы).

**ВАЛЮ'ТНЫЙ** *экон.*— валюта...-ы; *валютные операции* — валюта операцияләре.

**ВАЛЮ'ТЧИК** *м.*— валютчик (валюта белән спекуляция ясаучы).

**ВАЛЯ'ЛЬНЫЙ** — киез итек...-ы; *валяльная фабрика* — киез итек фабрикасы.

**ВАЛЯ'ЛЬНЯ** *ж.*— киез итек басу мастерское.

**ВАЛЯ'ЛЬЩИК** *м.*, **ВАЛЯ'ЛЬЩИЦА** *ж.*— киез итек басучы (эшче).

**ВА'ЛЯНЫЙ** — к. валеный.

**ВАЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. аунату; аунатып йөртү; *валять в снегу* — карда аунату; 2. *(бросая, катать)* тәгәрәтү; 3. әвәләү; *валять хлебы* — ипи әвәләү; 4. басу; *валять войлок* — киез басу; 5. *(делать небрежно)* ничек житте шулай эшләү; 6. чайкалдыру; *пароход валяло с боку на бок* — пароходны бер яктан икенче якка чайкалдыра иде; 7. *пов. накл.* **валяй, валяйте** — әйдә, эшли бир! әйдә, бара бир! әйдә, китә бир! ◇ **Валять на авось** — ни булса ул булыр дип эшләү; миннән киткәнче, иясенә житкәнче дип эшләү.

**ВАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. аунау; *валяться в снегу* — карда аунау; 2. аунап яту; *шапка валяется на полу* — бүрек идәндә аунап ята; 3. *(лежать, бездельничая)* тик яту, эшсез яту. ◇ **Валяться в ногах** — аяк астына егылу. **Валяется со смеху** — эче катып көлә. **На полу не валяется** — юлда ятмый, бушка килми.

**ВАМПИ'Р** *м.*— 1. вампир (а. *фольк.* өрәк, убыр; б. *зоол.* зур ярканат); 2. *перен.* канечкеч, явыз, эксплуататор, вампир.

**ВАНДА'Л** *м.*— вандал (1. борынгы герман кабиләсе; 2. культура памятникларын җимерүче, вәхши; 3. чиксез надан кеше).

**ВАНДАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — вандализм, вандаллык (1. культура памятникларын җимерү; 2. үтә тупаслык, үтә вәхшилек).

**ВАНИЛИ'Н** *м.*— ванилин (камырга тәм кертү өчен салына).

**ВАНИ'ЛЬ** *ж. мн.* нет, *бот.* — ваниль (тропик үсемлек һәм аның киптерелгән хуш исле кузагы).

**ВАНИ'ЛЬНЫЙ** — 1. ваниль ... -ы; *ванильный порошок* — ваниль порошогы; 2. ванильле; *ванильный шоколад* — ванильле шоколад.

**ВА'ННА** *ж.*— ванна. ◇ **Принимать солнечные ванны** — кояшта кызыну.

**ВА'ННАЯ** *ж.* — ванна бүлмәсе.

**ВА'НЬКА-ВСТА'НЬКА** *м.*— 1. аумас курчак; 2. *перен.* һәртөрле бәладән ансат котылучы.

**ВАР** *м.*— 1. *тех.* вәр, кайнатылган сумала; 2. *обл.* кайнар су.

**ВА'РВАР** *м.* — варвар (1. *истор.* борынгы грекларда һәм римлеләрдә — чит ил кешесе; 2. *перен.* тупас, надан кеше, вәхши, культура памятникларын җимерүче).

**ВАРВАРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — варварлаштыру; варварлашу; *война ведёт к варваризации населения* — сугыш халыкны варварлаштыруга алып бара.

**ВАРВАРИ'ЗМ** *м. лит.* — варваризм (чит телдән кергән һәм әдәби тел нормаларын боза торган сүз яки әйләнмә).

**ВА'РВАРСКИ** *нареч.*— тупас, каты, варварларча, вәхшиләрчә.

**ВА'РВАРСКИЙ** — 1. *истор.* варвар...; *варварские племена* — варвар кабиләләр; 2. *перен.* тупас, каты; *варварское обращение с детьми* — балалар белән тупас (каты) мөгамәлә; 3. *перен.* варварларча..., вәхшиләрчә...; *варварское отношение к памятникам искусства* — сәнгать памятникларына варварларча мөнәсәбәт.

**ВА'РВАРСТВО** *ср. мн.* нет— 1. варварлык, варварларча мөнәсәбәт; 2. тупаслык, вәхшилек, кансызлык.

**ВАРГА'НИТЬ** *несов. простореч.*— ничек житте шулай эшләү, аннан-моннан гына эшләү, начар эшләү.

**ВА'РЕВО** *ср. разг.*— кайнар шулпа.

**ВА'РЕЖКА** *ж.*— бияләй.

**ВАРЕНЕ'Ц** *м.*— катык, варенец.

**ВАРЕ'НИКИ** *мн. (ед.* вареник) — эремчек пилмәне, кәбестә пилмәне.

**ВАРЁНЫЙ** — 1. пешкән (суда), пешереп әзерләнгән; 2. *перен.* арыган, изрәгән.

**ВАРЕ'НЬЕ** *ср.*— варенье.

**ВАРИА'НТ** *м.*— вариант, төр.

**ВАРИАЦИО'ННЫЙ** — вариацион, вариацияле, үзгәрешле.

**ВАРИА'ЦИЯ** *ж.* — вариация (1. берәр нәрсәнең аерым детальләрендә, кисәкләрендә үзгәлек, төрлелек, мәсәлән, бер үк әкиятнең төрлечә сөйләнеп йөрүе; 2. *биол.*, төзелештә төп типтан читкә тайпылыш (хайваннарда һәм үсемлекләрдә); 3. *муз.* бер музыкаль теманың аерым төрләре).

**ВАРИ'ТЬ** *несов.*— 1. пешерү (суда), кайнатып пешерү; 2. кайнату; *варить пиво* — сыра кайнату. ◇ **Желудок хорошо варит** — ашказаны яхшы эшли. **Голова не варит** — баш эшләми. **Котелок варит** *шутл.* — башы эшли.

**ВАРИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. пешү (суда); 2. *страд.* пешерелү (суда). ◇ **Вариться в собственном соку** *разг.* — үз казанында кайнау.

**ВА'РКИЙ** — 1. *(о печи)* яхшы пешерә торган, күп эсселек бирә торган; 2. *простореч. (о пище)* тиз, яхшы пешә торган; 3. *охот. (о собаках)* тиз эзэрли торган.

**ВАРНА'К** *м. обл.*— качкын, каторжан; юлбасар, талаучы.

**ВАРФОЛОМЕ'ЕВСКАЯ НОЧЬ** — Варфоломей төне (1. 1572 нче елның 24 нче августка каршы төнендә Франциядә католикларның гугенотларны масса күләмдә үтерүе — суюы; 2. *перен.* бүтән карашта булучыларны масса күләмдә үтерү, кыру турында әйтелә).

**ВАРЬИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. *(разнообразить)* төрлеләндерү, үзгәртү; 2. *(видоизменяться)* үзгәрү (билгеле чикләр арасында үзгәреп, алмашынып тору).

**ВАРЬИ'РОВАТЬСЯ** *несов.* — 1. үзгәрү, төрлеләнү; 2. *страд.* үзгәртелү, төрлеләндерелү.

**ВАРЯ'ГИ** *мн. истор.*— варяглар (Скандинавиядән чыккан норман кабиләсенең исеме; бу кабилә, кораллы дружиналар оештырып, көнчыгыш славяннар территориясенә һөҗүмнәр ясый торган булган).

**ВАС** — 1. сезне; *жду вас* — сезне көтәм; 2. сездән; *прошу вас* — сездән үтенәм; 3. *говорим о вас* — сезнең турыда сөйлибез.

**ВАСИЛЁК** *м. бот.*— күкчәчәк, күкбаш.

**ВАСИЛИ'СК** *м.*— 1. *миф.* юха елан, аждаһа; 2. *зоол.* кәлтә елан(ның бер төре).

**ВАСИЛЬКО'ВЫЙ** — 1. күкчәчәк...-ы; *васильковый стебель* — күкчәчәк сабагы; 2. аксыл зәңгәр; *васильковое платье* — аксыл зәңгәр күлмәк. ◇ **Васильковые глаза** — зәңгәр күзләр.

**ВАССА'Л** *м.*— вассал (1. *истор.* феодализм чорында эре феодалга буйсынган кечерәк феодал; 2. *перен.* зур дәүләткә буйсынган кечкенә дәүләт; 3. капиталистик илләрдә зур дәрәҗәле кешегә буйсынган түбән дәрәҗәле кеше).

**ВАССА'ЛЬНЫЙ** *истор.*—1. вассал..., бәйле; *вассальное государство*—вассал дәүләт; 2. вассаллык...-ы; *вассальное отношение* — вассалык мөнәсәбәте.

**ВА'ТА** *ж. мн.* нет— мамык.

**ВАТА'ГА** *ж. разг.*— төркем, өер.

**ВА'ТЕР-МАШИ'НА** *ж. тех.*— ватер-машина, эрләү машинасы.
**ВА'ТЕРНЫЙ: ватерный цех** — эрләү цехы.
**ВАТЕРПА'С** *м. тех.* — ватерпас, тигезләгеч (горизонталь тигезлекне билгеләү приборы).
**ВАТЕРПО'ЛО** *ср. нескл. спорт.*— ватерполо (суда ике команда арасында уйнала торган туп уены).
**ВАТИКА'Н** *м.*— Ватикан (Рим папасының даими резиденциясе).
**ВАТИ'Н** *м. мн.* нет — ватин (кием эченә жылылык өчен салына торган трикотаж тукыма).
**ВА'ТНЫЙ** — 1. мамык...; *ватный тампон* — мамык тампон; 2. мамык...-ы; *ватное производство* — мамык производствосы; 3. *(сделанный на вате)* мамыклы, мамык салынган.
**ВАТРУ'ШЕЧНЫЙ** — ватрушка...-ы, пәрәмәч...-ы; *ватрушечное тесто* — ватрушка камыры, пәрәмәч камыры.
**ВАТРУ'ШКА** *ж. кулин.* — ватрушка, эремчек пәрәмәче, бәрәнге пәрәмәче һ. б.
**ВАТТ** *м. тех.*— ватт (җегәрлекне үлчәү берәмлеге).
**ВА'ФЕЛЬНИЦА** *ж.*— вафельница (вафля ясау приборы).
**ВА'ФЕЛЬНЫЙ** — вафля... -ы; *вафельное производство* — вафля производствосы.
**ВА'ФЕЛЬЩИК** *м.*, **ВА'ФЕЛЬЩИЦА** *ж.*— вафля ясаучы, вафля сатучы.
**ВА'ФЛЯ** *ж. кулин.*— вафля (кәрәзсыман юка печенье).
**ВАХЛА'К** I *м. разг. бран.*— 1. шапшак кыяфәтле кеше; 2. тәрбиясез кеше, тупас кеше, булдыксыз кеше.
**ВАХЛА'К** II *м. простореч. обл.*— шеш.
**ВА'ХМИСТР** *м. устар.*— вахмистр (патша армиясендә атлы гаскәр унтер-офицеры).
**ВА'ХТА** *ж.*— вахта (1. корабльдә дежур тору, кизү тору; 2. дежур тора торган сменаның составы; 3. *перен.* берәр вакыйга унае белән фидакарьләрчә эшләү һәм шуның нәтиҗәсендә хезмәт житештерүчәнлеген күтәрүгә ирешү, мәсәлән, *встать на вахту мира* — тынычлык вахтасына басу, ягъни дөньяда тынычлык саклауга багышлап үткәрелә торган кампания унае белән фидакарьләрчә эшләү).
**ВА'ХТЕННЫЙ** — 1. вахта...-ы; *вахтенный начальник* — вахта начальнигы; 2. *в знач. сущ.* вахтенный (хәрби корабльдә каравылда торучы, дежурда торучы).
**ВА'ХТЕР** *м.* — вахтер, өлкән сакчы (учреждениедә).
**ВА'ХТЕРСКИЙ**— вахтерлык...-ы; *вахтерская служба* — вахтерлык хезмәте.
**ВАХТО'ВНИК** *м. бот.*— ак төнбоек.
**ВАШ, ВА'ША, ВА'ШЕ, ВА'ШИ** — сезнең, сезнеке. ◇ **Ваши** — сезнекеләр, сезнең туганнар, сезгә якыннар. **По-вашему** — сезнеңчә. **Ваш брат** — сезнең халык, сезнең ише халык. **И вашим и нашим** — аумакай; икейөзле, мөнафикъ.

**ВА'ШГЕРД** *м. тех.*— вашгерд (руда юу аппараты).
**ВАЯ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. скульптура, сынлы сәнгать; 2. к. ваять.
**ВАЯ'ТЕЛЬ** *м. устар.*— скульптор, сынлы сәнгатьче.
**ВАЯ'ТЬ** *несов.* — юнып ясау, кырып ясау, чокып ясау, әвәләп ясау (сынлы сурәтне).
**ВБЕГА'ТЬ** *несов.*— к. вбежать.
**ВБЕЖА'ТЬ** *сов.*— 1. йөгереп керү, йөгереп килеп керү, йөгереп кереп китү, чабып керү; чабып килеп керү; 2. *перен.* килеп керү, барып керү; *... и вбежишь... в изумительную жизнь* — ... һәм гаҗәп бер тормышка килеп (барып) керерсең.
**ВБИВА'ТЬ** *несов.*— к. вбить.
**ВБИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — кагып кертелү.
**ВБИРА'ТЬ** *несов.*— эчкә суыру, эчкә тарту, эчкә алу, йоту (суны, һаваны); сеңдерү.
**ВБИРА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. сеңү; 2. *страд.* эчкә суырылу, эчкә тартылу (су, һава); сеңдерелү.
**ВБИТЬ** *сов.*— кагып кертү; бәреп кертү; *вбить мяч в гол* — голга туп бәреп кертү. ◇ **Вбить в голову** — башка туку. **Вбить клин** — чөй кагу, ара бозу, дошманлаштыру.
**ВБЛИЗИ'** — 1. *нареч.* якында, якыннан; *дальнозоркий вблизи хуже видит* — ерактан күрүче якыннан начаррак күрә; 2. *предлог* янында; *вблизи моря* — диңгез янында.
**ВБОК** *нареч.*— янга, читкә, бер якка, бер кырыйга.
**ВБРА'СЫВАТЬ** *несов.*— к. вбросить.
**ВБРА'СЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — эчкә ташлану, эчкә ыргытылу.
**ВБРОД** *нареч.*— су ерып, су сөреп; *перейти реку вброд* — елганың бер ягыннан икенче ягына су ерып чыгу.
**ВБРОСА'ТЬ** *сов.*— к. вбросить.
**ВБРО'СИТЬ** *сов.* — эчкә ыргыту, эчкә ташлау.
**ВБРО'СИТЬСЯ** *сов.*— к. вбрасываться.
**ВБУ'ХАТЬ** *сов. простореч.* — күп итеп салу, салып бетерү; *он вбухал в печенье весь сахарный песок* — ул печеньегә барлык шикәр комын салып бетергән.
**ВБУ'ХАТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. лап итеп егылу; 2. *перен.* уңайсыз хәлгә төшү.
**ВБУ'ХНУТЬ** *сов. простореч.*— 1. к. вбухать; 2. к. вбухаться.
**ВБУ'ХНУТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. вбухаться.
**ВВА'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. ввалить.
**ВВАЛИВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. ввалиться.
**ВВАЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. эчкә ыргыту, эчкә ташлау, эчкә аудару (берәр авыр әйберне); 2. *простореч.* дөмбәсләү, кыйнау, кундырып алу.
**ВВАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. егылып төшү, егылу (эчкә); *ввалиться в яму* — чокырга егылып төшү; 2. эчкә бату, эчкә батып керү; ябышу; *у больного ввалились глаза* — авыруның күзләре эчкә баткан, эчкә батып кергән; *у больного ввалились щёки* — авыруның яңагы яңакка ябышкан; эчкә батып кергән. 3. *(тяжеловесно войти)* лап-лап атлап килеп керү, тупас рәвештә килеп

керү; 4. *(неожиданно вломиться)* чакырусыз килеп керү. ◇ **Бока ввалились** — эче суырылып кергән, эче тартылган, „эче эчкә ябышкан.

**ВВЕДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. вводить; 2. кереш; *введение в философию* — философиягә кереш; 3. кереш сүз, сүз башы; *введение к книге* — китапка кереш сүз.

**ВВЕЗТИ'** *сов.* — к. ввозить.

**ВВЕ'К** *нареч.* — бервакытта да, беркайчан да, мәңге, мәңгегә, гомергә; *ввек не забуду* — гомергә онытмам, гомергә онытасым юк.

**ВВЕРГА'ТЬ** *несов. устар.* — 1. *(насильно заключать)* көчләп кертү, ябу, утырту ташлау, салу; *ввергать в темницу* — төрмәгә ябу; 2. төшерү, сабыштыру; *ввергать в скорбь* — кайгыга төшерү; 3. *(втягивать, вовлекать)* дучар итү, кертү.

**ВВЕРГА'ТЬСЯ** *несов. устар.* — 1. көчләп утыртылу, ябылу; 2. төшү, дучар булу; *ввергаться в печаль* — кайгыга төшү.

**ВВЕ'РГНУТЬ** *сов.* — к. ввергать.

**ВВЕ'РЕННЫЙ** — 1. ышанып тапшырылган; 2. карамагындагы, карамагында булган; *вверенное мне учреждение* — минем карамагымдагы учреждение.

**ВВЕ'РЗИТЬСЯ** *сов. разг. вульг.* — пычракка егылу, бату.

**ВВЕ'РИТЬ** *сов.* — ышанып тапшыру, ышанып әйтү; (кемнең дә булса) карамагына бирү.

**ВВЕ'РИТЬСЯ** *сов.* — тулысынча ышану, ышанып бирелү, таяну (кемгә дә булса).

**ВВЕРНУ'ТЬ** *сов.* — 1. *тех. (ввинтить)* борып кертү, винтлап кертү; 2. *перен.* кушу, кыстыру, катнаштыру (сүз); *ввернуть словечко* — сүз кыстыру.

**ВВЕРСТА'ТЬ** *сов. тип.* — вёрсткага кертү.

**ВВЁРСТЫВАТЬ** *несов.* — к. ввёрстать.

**ВВЁРСТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — вёрсткага кертелү.

**ВВЕРТЕ'ТЬ** *сов. разг.* — борып кертү, борып-борып кертү.

**ВВЁРТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. ввертеть.

**ВВЁРТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — борып кертелү, борып-борып кертелү.

**ВВЕРХ** *нареч.* — өскә, югарыга, өскә таба. ◇ **Вверх дном (ногами, тормашками)** — асты өскә; *всё вверх дном пошло* — бөтен нәрсәнең асты өскә килде. **Руки вверх!** — кулларыңны күтәр!

**ВВЕРХУ'** *нареч.* — өстә, югарыда.

**ВВЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. вверить.

**ВВЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. ввериться; 2. *страд.* ышанып тапшырылу, (кемнең дә булса) карамагына бирелү.

**ВВЕСТИ'** *сов.* — к. вводить.

**ВВЕСТИ'СЬ** *сов.* — к. вводиться.

**ВВЕЧЕРУ'** *нареч. устар.* — кич белән, кичен, кичкырын.

**ВВИВА'ТЬ** *несов.* — к. ввить.

**ВВИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — кушып үрелү, кушып ишелү, кертеп үрелү.

**ВВИДУ'** *предлог* —...-лыктан, ...-ганлыктан, ...-га күрә, бул(ма)ганлыктан, булу сәбәпле, исәпкә алып.

**ВВИНТИ'ТЬ** *сов.* — борып кертү, винтлап кертү.

**ВВИ'НЧИВАТЬ** *несов.* — к. ввинтить.

**ВВИТЬ** *сов.* — кушып үрү, кушып ишү, кертеп үрү, кертеп ишү.

**ВВОД** *м.* — 1. *(действие)* кертү; 2. кертү урыны, кертелгән урын; *электрический ввод* — электр кертелгән урын.

**ВВОДИ'ТЬ** *несов.* — 1. кертү, алып керү; 2. җибәрү; *вводить лекарство в вену* — венага дару җибәрү. ◇ **Вводить в семью** — семьяга алу, үз семьяңа кертү. **Вводить в заблуждение** — ялгыш юлга кертү, төшерү; ялгыштыру. **Вводить в курс дела** — эшнең асылы белән таныштыру. **Вводить в эксплуатацию** — эксплуатациягә бирү. **Вводить новые приёмы в науку** — фәнгә яңа алымнар кертү. **Вводить во владение, в наследство** — милекне, мирасны рәсми рәвештә тапшыру.

**ВВОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. кертелү; 2. җибәрелү (мәсәлән, дару); 3. алыну (мәсәлән, семьяга); 4. төшерелү (мәсәлән, ялгыш юлга); 5. таныштырылу, төшендерелү (мәсәлән, эшнең асылы белән); 6. бирелү, кертелү (мәсәлән, эксплуатациягә); 7. кертелү; кертеп җибәрелү (мәсәлән, яңа алымнар).

**ВВО'ДНЫЙ** — 1. тапшыру...-ы; *вводный лист* — тапшыру кәгазе (мирасны, милекне); 2. кереш...; *вводная статья* — кереш мәкалә; 3. очраклы; *я здесь только вводное лицо* — мин биредә тик очраклы кеше генә. ◇ **Вводное слово, вводное предложение** *грам.* — кереш сүз, кереш җөмлә.

**ВВОЗ** *м. мн.* нет, *экон.* — 1. кертү, алу; *ввоз машин из-за границы* — чит илләрдән машиналар кертү; 2. импорт (чит илләрдән кертелгән товарлар).

**ВВОЗИ'ТЬ** *несов.* — читтән кертү, кертү, китерү, китертү.

**ВВОЗИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — читтән кертелү, кертелү, китерелү.

**ВВО'ЗНЫЙ** — 1. читтән кертелгән; *ввозный товар* — читтән кертелгән товар; 2. читтән кертелгән товарларга салына торган; *ввозная пошлина* — читтән кертелгән товарларга салына торган пошлина.

**ВВОЛА'КИВАТЬ** *несов. простореч.* — өстерәп кертү, сөйрәп кертү, өстерәп алып керү.

**ВВОЛА'КИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — өстерәп кертелү, сөйрәп кертелү.

**ВВОЛО'ЧЬ** *сов. простореч.* — к. вволакивать.

**ВВО'ЛЮ** *нареч. разг.* — теләгәнчә, туйганчы, теләгән чаклы, иркенләп.

**ВВО'СЬМЕРО** *нареч.* — 1. сигез тапкыр, сигез мәртәбә, сигез өлеш; 2. сигез тапкыр артыграк.

**ВВОСЬМЕРО'М** *нареч.* — сигезәү, сигезәү бергәләп, сигез кеше бергә.

**В-ВОСЬМЫ'Х** *ввод. сл.* — сигезенчедән.

**ВВЫСЬ** *нареч.* — югарыга, өскә.

**ВВЯЗА'ТЬ** *сов.* — 1. кушып бәйләү, кертеп бәйләү, кыстырып бәйләү (мәсәлән, кара оекка кызыл җеп кушып); 2. *перен.* бутау;

*ввязать кого-н. в неприятное дело* — кемне дә булса күңелсез эшкә бутау.

**ВВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. ввязать.

**ВВЯЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. катышу, тыгылу; 2. *(взяться)* алыну.

**ВВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. ввязаться; 2. *страд.* кушып бәйләнү, кыстырып бәйләнү.

**ВГИБ** *м.* — батынкы урын, эчкә баткан урын, батып кергән урын.

**ВГИБА'ТЬ** *несов.* — к. вогнуть.

**ВГИБА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — эчкә таба бөгелү; бөгеп кертелү.

**ВГЛУБЬ** I *нареч.* — тирәнгә, тирәнгә таба; *измерить озеро вглубь* — күлне тирәнгә үлчәү; күлнең тирәнлеген үлчәү.

**ВГЛУБЬ** II *предлог* — эченә, эченә үк; *вглубь леса* — урман эченә.

**ВГЛЯДЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. текәлеп карау; *вгляделся в прохожего и узнал в нём своего знакомого* — узып баручыга текәлеп карый торгач аның танышым икәнлеген белдем; 2. озак (еш) карый торгач күнегү.

**ВГЛЯ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. вглядеться.

**ВГНЕЗДИ'ТЬСЯ** *сов.* — нык урнашу, кереп урнашу, урнашып калу.

**ВГОЛОВА'Х** *нареч.* — баш очында.

**ВГОНЯ'ТЬ** *несов.* — 1. *(загнать)* куып кертү; 2. *простореч. (вбивать)* кагып кертү; 3. *(втеснять)* тыгызлап кертү, дыңгычлап кертү. ◇ **Вгонять в чахотку** — чахоткага сабыштыру. **Вгонять в пот** — тиргә батыру, тиргә төшерү, интектерү. **Вгонять в гроб** — гүргә кертү, үләр хәлгә житкерү. **Вгонять в краску** — йөзен кызарту, оялту.

**ВГОНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. куып кертелү; 2. кагып кертелү; 3. тыгызлап кертелү, дыңгычлап кертелү.

**ВГОРЯЧА'Х** *нареч.* — кызып, ярсып, кызып китеп, кызган хәлдә.

**ВГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — тешләр белән эләктереп алу, тешләрне батырып кертү.

**ВГРЫ'ЗТЬСЯ** *сов.* — к. вгрызаться.

**ВДАВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. вдаться.

**ВДАВИ'ТЬ** *сов.* — басып кертү, сытып кертү, кысып кертү; яньчү.

**ВДАВИ'ТЬСЯ** *сов.* — кысылып керү, басылып керү, яньчелеп керү.

**ВДА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. вдавить.

**ВДА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. вдавиться; 2. *страд.* кысып кертелү.

**ВДА'ЛБЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. вдолбить.

**ВДАЛЕКЕ'** *нареч.* — еракта.

**ВДАЛИ'** *нареч.* — к. вдалеке.

**ВДАЛЬ** *нареч.* — еракка.

**ВДА'РИТЬ** *сов. простореч.* — сугу, кундыру, тондыру.

**ВДА'ТЬСЯ** *сов.* — эчкә кереп тору. ◇ **Вдаться в подробности** — жентекләп сөйләү, детальләргә бирелеп китү; мәсьәләнең деталенә керү; детальләре белән кызыксыну; жентекләп өйрәнү.

**ВДВИГА'ТЬ** *несов.* — к. вдвинуть.

**ВДВИГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. вдвинуться; 2. *страд.* этәреп кертелү, шудырып кертелү.

**ВДВИЖНО'Й** — шудырмалы, этәрмәле, шудырып кертелә торган, этәреп кертелә торган.

**ВДВИ'НУТЬ** *сов.* — этәреп кертү, шудырып кертү.

**ВДВИ'НУТЬСЯ** *сов.* — эчкә таба керү, кереп утыру.

**ВДВО'Е** *нареч.* — 1. ике тапкыр, ике мәртәбә, икеләтә; *вдвое меньше* — ике тапкыр (икеләтә) кечкенәрәк; 2. икегә, урталай; *сложить лист бумаги вдвое* — бер бит кәгазьне икегә (урталай) бөкләү.

**ВДВОЁМ** *нареч.* — икәү, икәүләп, икәүләшеп, икәү бергә.

**ВДВОЙНЕ'** *нареч.* — 1. ике тапкыр артык, икеләтә артык; 2. *перен.* һич тә, бөтенләй; *он вдвойне неправ* — ул һич тә хаклы түгел, ул бөтенләй хаксыз.

**ВДЕВА'ТЬ** *несов.* — к. вдеть.

**ВДЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. вдеться.

**ВДЕ'ВЯТЕРО** *нареч.* — 1. тугыз тапкыр, тугыз мәртәбә, тугыз өлеш; *вдевятеро больше* — тугыз тапкыр зуррак; 2. тугыз тапкыр артыграк; *взять чего-н. вдевятеро* — берәр нәрсәне тугыз тапкыр артыграк алу.

**ВДЕВЯТЕРО'М** *нареч.* — тугызау, тугызау бергә.

**В-ДЕВЯ'ТЫХ** *ввод. сл.* — тугызынчыдан.

**ВДЕ'ЛАТЬ** *сов.* — кертеп урнаштыру, кую, кертеп кую, кертеп ныгыту; *вделать камень в кольцо* — йөзеккә каш кую; *вделать несгораемый шкаф в стену* — янмый торган шкафны стенага кертеп урнаштыру.

**ВДЕ'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. вделать.

**ВДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кертеп урнаштырылу, кертеп куелу, кертеп ныгытылу.

**ВДЁРГИВАТЬ** *несов.* — к. вдёрнуть.

**ВДЁРНУТЬ** *сов.* — эчкә тартып кертү, тартып кертү; *вдёрнуть сани в сарай* — чананы сарайга тартып кертү. ◇ **Вдёрнуть нитку в иголку** — инә саплау.

**ВДЕ'СЯТЕРО** *нареч.* — 1. ун тапкыр, ун мәртәбә, ун өлеш; 2. ун тапкыр артыграк.

**ВДЕСЯТЕРО'М** *нареч.* — унау, унау бергә.

**В-ДЕСЯ'ТЫХ** *ввод. сл.* — унынчыдан.

**ВДЕТЬ** *сов.* — 1. *(нитку)* саплау, кигезү; 2. *(вообще)* тыгу, кертү; *вденешь ногу в стремя* — аягыңны өзәңгегә тыгарсың.

**ВДЕ'ТЬСЯ** *сов.* — кигезелү, саплану (жеп).

**ВДОБА'ВОК** *нареч.* — өстәвенә, шуның өстенә, аннан тыш, житмәсә тагын.

**ВДОВА'** *ж.* — тол хатын.

**ВДОВЕ'ТЬ** *несов.* — тол яшәү, тол булып яшәү; *она вдовеет третий год* — ул өченче ел тол яши.

**ВДОВЕ'Ц** *м.* — тол ир.

**ВДО'ВИЙ** — тол хатын...-ы; *вдовья жизнь* — тол хатын тормышы.

**ВДОВИ'ЦА** *ж.* — к. вдова.

**ВДО'ВОЛЬ** *нареч.* — 1. *(вволю)* туйганчы, теләгәнче, житәрлек, күпме кирәк булса, шул кадәр; 2. *в знач. сказ.* күп, мул, житеш, житәрлек; *у нас всего вдоволь* — бездә бөтен нәрсә дә житәрлек.

**ВДОВСТВО'** *ср. мн.* нет — толлык.

**ВДО'ВСТВОВАТЬ** *несов.*—толлыкта яшәү, тол булып яшәү.

**ВДО'ВУШКА** *ж.*— к. вдова.

**ВДО'ВЫЙ** — тол калган, тол яшәүче.

**ВДОГО'НКУ** *нареч.*— артыннан; *крикнуть вдогонку* — артыннан кычкыру.

**ВДОЛБИ'ТЬ** *сов.*— 1. кагу, кагып кертү; 2. *перен.* туку, тукып кертү (башына), көчхәл белән аңлатып бирү, көчкә аңлатып бирү.

**ВДОЛЬ** — 1. *предлог* буйлап, буенча; *вдоль реки* — елга буйлап; 2. *нареч.* буйга; *разрезать материю вдоль* — материяне буйга кисү. ◇ **Вдоль и поперёк** — 1. аркылыга-буйга; *изъездить Европу вдоль и поперёк* — Европаны аркылыга-буйга йөреп чыгу; 2. *перен.* бик ныклап, жентекләп; *я изучил эту книгу вдоль и поперёк* — мин бу китапны бик ныклап тикшереп чыктым.

**ВДО'СТАЛЬ** *нареч.*— 1. к. вдоволь; 2. *устар.* калдырмыйча, бөтенләй

**ВДОХ** *м.*— сулыш алу, эчкә сулау.

**ВДОХНОВЕ'НИЕ** *ср.*— илһам, дәрт, ижади күтәренкелек.

**ВДОХНОВЕ'ННО** *нареч.*— дәрт белән, илһам белән, дәртләнеп, рухланып.

**ВДОХНОВЕ'ННЫЙ** — илһамлы, дәртле, илһамланган, дәртләнгән.

**ВДОХНОВИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ВДОХНОВИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— 1. *(тот, кто вдохновляет)* илһамландыручы, дәртләндерүче, илһам бирүче, рухландыручы; 2. *(тот, кто подстрекает)* котыртучы.

**ВДОХНОВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — илһамландыргыч, дәртләндергеч, рухландыргыч.

**ВДОХНОВИ'ТЬ** *сов.*— 1. *(воодушевить)* дәртләндерү, дәрт бирү, дәрт кертү, рухландыру, рух күтәрү, илһамландыру, илһам кертү, күңел күтәрү; 2. *(подстрекнуть)* котырту.

**ВДОХНОВИ'ТЬСЯ** *сов.*— дәртләнү, рухлану, рух күтәрелү.

**ВДОХНОВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. вдохновить.

**ВДОХНОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. вдохновиться; 2. *страд.* дәртләндерелү, рухландырылу.

**ВДОХНУ'ТЬ** *сов.*— 1. сулау; сулыш алу, эчкә таба сулау; 2. уяту, кузгату; *вдохнуть чувство гордости* — горурлык хисе уяту. ◇ **Вдохнуть жизнь в какое-нибудь дело** — нинди дә булса эшне җанландырып җибәрү.

**ВДРЕ'БЕЗГИ** *нареч.*— 1. челпәрәмә; *разбить вдребезги* — челпәрәмә китерү (вату); 2. тәмам, лаякыл, аңын югалтканчы; *вдребезги пьян* — тәмам (лаякыл) исерек.

**ВДРУГ** *нареч.*— көтмәгәндә, кинәт, капыл, искәрмәстән. ◇ **Все вдруг** — барысы да (барыбыз да, барыгыз да) берьюлы. **Всё вдруг** — барын да берьюлы. **Вдруг, а вдруг** — әгәр, әгәр дә; *а вдруг ошиблись* — әгәр дә ялгышкан булсалар.

**ВДРЫЗГ** *нареч. простореч.*— к. вдребезги. ◇ **Кулаком разбил ему вдрызг лицо** — йодрыгы белән сугып авызын-борынын җимерде.

**ВДУВА'НИЕ** *ср.*— 1. к. вдувать; 2. *мед.* *(в лёгкие)* вдувание (авыру үпкәне кысу өчен газ җибәрү).

**ВДУВА'ТЬ** *несов.* — өреп тутыру, өреп кертү, өреп һава тутыру; *вдувать воздух в резиновый мяч* — резин тупка һава өреп тутыру.

**ВДУВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— өреп тутырылу, өреп кертелү, өреп һава тутырылу.

**ВДУ'МАТЬСЯ** *сов.* — уйга чуму, тирәнтен уйлау.

**ВДУ'МЧИВО** *нареч.*—1. *(глубоко вникая)* төптән уйлап, тирәнтен уйлап; 2. *(задумчиво)* уйланып.

**ВДУ'МЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. төптән уйлау, җентекләп уйлау, тирәнтен төшенү; 2. житдилек, уйчанлык.

**ВДУ'МЧИВЫЙ** — 1. *(глубоко вникающий)* төптән уйлаучан, җентекләп уйлаучан, мәсьәләгә тирәнтен төшенүчән, тирәнтен уйлап эш итүчән; 2. уйчан; *вдумчивое лицо* — уйчан йөз.

**ВДУ'МЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. вдуматься.

**ВДУ'НУТЬ** *сов. однокр.*— к. вдувать.

**ВДУТЬ** *сов. простореч.*— к. вдувать.

**ВДЫХА'ТЕЛЬНЫЙ** — сулыш алу...-ы, тын алу...-ы, эчкә сулау...-ы; *вдыхательное движение* — сулыш алу хәрәкәте.

**ВДЫХА'ТЬ** *несов.*— к. вдохнуть.

**ВДЫХА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— сулыш алыну, тын алыну, эчкә сулану.

**ВЕГЕТАРИ'АНЕЦ** *м.*— вегетарианец, вегетариан (1. ит ашамыйча, үсемлекләрдән хәзерләнгән азыклар белән генә туенучы; вегетарианлык тарафдары; 2. *перен. ирон.* политик көрәштә көч куллануга, көчләүгә, катгый чаралар күрүгә каршы кеше).

**ВЕГЕТАРИА'НСКИЙ** — 1. вегетарианнар...-ы, вегетарианлык...-ы; *вегетарианское общество* — вегетарианнар җәмгыяте; *вегетарианские убеждения* — вегетарианлык карашлары, 2. итсез, итсез пешерелгән; итсез ашамлыклар...-ы; *вегетарианский суп* — итсез шулпа.

**ВЕГЕТАРИА'НСТВО** *ср. мн.* нет — вегетарианлык (ит ашамау, ягъни яшелчә һәм сөт азыклары белән генә туенып тору).

**ВЕГЕТАРИА'НСТВОВАТЬ** *несов.*— вегетариан булу, ит ашамау.

**ВЕГЕТАТИ'ВНЫЙ** *биол.* — вегетатив (үстерә торган, тукландыра торган, үсү белән идарә итә торган); *вегетативные органы* — вегетатив органнар (үсемлекләрнең үстерә һәм тукландыра торган органнары). ◇ **Вегетативное размножение** — вегетатив үрчү (җенессез үрчү). **Вегетативная система** — вегетатив система (нервлар системасының кан әйләнеше, сулыш алу һ. б. белән идарә итә торган өлеше).

**ВЕГЕТАЦИО'ННЫЙ** *бот.*— вегетацион, вегетация...-ы; *вегетационный период* — вегетацион чор, вегетация чоры (үсемлекнең үсүе, җитлегүе, үрчүе өчен киткән вакыт).

**ВЕГЕТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — вегетация (үсемлекләрнең үсү, җитлегү, үрчү процессы).

**ВЕ'ДАТЬ** *несов. устар.*— 1. *(знать)* белү, хәбәрдар булу, таныш булу; 2. *(управлять)* идарә итү, башкару, күзәтеп тору.

**ВЕ'ДАТЬСЯ** *несов. страд.*— идарә ителү, башкарылу.

**ВЕ'ДЕНИЕ: быть, находиться в ведении** *кого-н.*— кемнең дә булса карамагында булу; **принимать в своё ведение** — үз карамагына алу; **вне моего ведения** — минем карамагымнан тыш.

**ВЕДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. алып бару; *ведение заседания* — утырышны алып бару; 2. йөртү, башкару; *ведение дела* — эшне башкару; 3. житәкчелек итү; *ведение хозяйства* — хуҗалыкка житәкчелек итү.

**ВЕДЁРКО** *ср.*— кечкенә чиләк.

**ВЕДЁРНЫЙ** — 1. бер чиләк сыешлы, бер чиләкле; *ведёрный бочонок* — бер чиләк сыешлы мичкә; 2. чиләк...-ы; *ведёрная ручка* — чиләк тоткасы; *ведёрный мастер* — чиләк остасы.

**ВЕДОВСКО'Й** — сихерчелек...-ы, багучылык...-ы, күрәзәчелек...-ы; *ведовское дело* — сихерчелек эше.

**ВЕДОВСТВО'** *ср. мн.* нет — сихерчелек, багучылык, күрәзәчелек.

**ВЕ'ДОМО** I: **с ведома** — алдан белдереп, (кемнендер) рөхсәте белән, (кемнендер) ризалыгы белән; **без ведома** — алдан белдермичә, әйтмичә, (кемнең дә булса) рөхсәтеннән башка, ризалыгыннан башка.

**ВЕ'ДОМО** II *ввод. сл.*— билгеле, мәгълүм.

**ВЕ'ДОМОСТЬ** *ж.*— 1. ведомость; *ведомость расходов* — чыгымнар ведомосте; 2. *только мн.* хәбәрләр; *Ведомости Верховного Совета СССР* — СССР Верховный Советы хәбәрләре (СССР Верховный Советы кабул иткән карарлар һәм СССР Верховный Советы Президиумы Указлары басыла торган газета).

**ВЕ'ДОМСТВЕННЫЙ** — ведомство...-ы; *ведомственные издания* — ведомство басмалары. ◇ **Ведомственный подход к делу** — үз ведомствоң, учреждениең интересларыннан гына чыгып эш итү.

**ВЕ'ДОМСТВО** *ср.*— ведомство (дәүләт идарәсенең аерым тармагын алып бара торган учреждениеләр системасы).

**ВЕ'ДОМЫЙ** *устар.*— билгеле, таныш.

**ВЕДО'МЫЙ** — алып барыла торган; *корабль, ведомый опытным лоцманом* — тәҗрибәле лоцман тарафыннан алып барыла торган корабль.

**ВЕ'ДРЕНЫЙ** *устар.*— аяз, ачык (көн, һава турында).

**ВЕДРО'** *ср. (мн. вёдра)* — чиләк. ◇ **Льёт, как из ведра** — чиләкләп коя, чиләкләп койгандай ява.

**ВЁДРО** *ср. мн.* нет— (җәйге) аяз һава.

**ВЕДУ'ЩИЙ** — 1. алып баручы, алып бара торган; *инженеры, ведущие строительные работы* — төзү эшләре алып баручы инженерлар; 2. башлап баручы, алдан баручы, ияртеп баручы, алдынгы; *ведущий самолёт* — алдан баручы самолёт; 3. житәкче, житәкләп баручы, житәкчелек...-ы, житәкчелек итүче, житәкчелек итү...-ы; *ведущая роль партии* — партиянең житәкчелек роле; *ведущая роль науки* — фәннен житәкчелек роле; 4. *тех.* хәрәкәтләндерүче, хәрәкәткә китерүче, хәрәкәтләндергеч; *ведущее колесо* — хәрәкәтләндерүче көпчәк, хәрәкәтләндергеч көпчәк.

**ВЕДЬ** — бит, ич, лабаса; *ведь не ребёнок же я, сам понимаю* — мин бала түгел ләбаса, үзем дә аңлыйм.

**ВЕ'ДЬМА** *ж.*— 1. *миф.* сихерче карчык, убырлы карчык, жен карчыгы; 2. *перен. бран. вульг.* убырлы карчык, жен карчыгы (усал, әшәке кыяфәтле хатын турында).

**ВЕ'ДЫ** *мн.*— ведалар (һиндлеләрнең иң борынгы дини китаплары).

**ВЕ'ЕР** *м.*— җилпәзә, җилпәвеч, җилләткеч, веер.

**ВЕ'ЕРОМ** *в знач. нареч.*— ярым түгәрәк булып.

**ВЕ'ЕРНЫЙ** — 1. җилпәзә...-ы; җилпәзәләр...-ы; *веерная мастерская*—җилпәзәләр мастерское; 2. җилпәзәсыман; *веерные листы* — җилпәзәсыман яфраклар.

**ВЕЕРООБРА'ЗНЫЙ** — җилпәзәсыман.

**ВЕ'ЖЛИВО** *нареч.*— әдәп белән, нәзакәт белән, ихтирам белән; әдәплелек күрсәтеп, түбәнчелек күрсәтеп.

**ВЕ'ЖЛИВОСТЬ** *ж.*— 1. *только ед.* әдәплелек, тәрбиялелек, нәзакәтлелек, ихтирамлылык; 2. *только мн. устар.* ягымлы сүзләр, ягымлы мөгамәләләр.

**ВЕ'ЖЛИВЫЙ** — 1. әдәпле, тәрбияле, нәзакәтле, ихтирамлы; *вежливый человек* — әдәпле кеше; 2. күркәм, мөлаем; *вежливое обращение* — күркәм мөгамәлә.

**ВЕЗДЕ', ВЕЗДЕ И ВСЮДУ** *нареч.*— һәр җирдә, һәркайда.

**ВЕЗДЕСУ'ЩИЙ** — 1. *церк.* һәр җирдә, һәр урында була торган, һәр җирдә булучы; 2. *разг. ирон.* барысына да житешә торган, барысына да катнашучан, тыгылучан, һәр җиргә өлгерүчән.

**ВЕЗДЕХО'Д** *м.*— вездеход (теләсә нинди юлдан йөри ала торган автомобиль).

**ВЕЗЁТ** — к. везти.

**ВЕЗИ'РЬ** *м.*— к. визирь.

**ВЕЗТИ'** *несов.*— 1. утыртып яки төяп алып бару, алып килү, илтү, китерү; тартып алып бару (алып килү); 2. *безл. разг.* җай килеп тору, эше уңышлы бару, уңу, бәхете (м) булу; *в последнее время ему не везёт* — соңгы вакытта аның эше уңышлы бармый; *мне везёт* — миңа җай килеп тора; *ему везёт* — аның эше уңышлы бара (аның бүресе улый).

**ВЕЗТИ'СЬ** *несов.*— 1. *страд.* илтелү, китерелү (төяп, утыртып); 2. *разг. (тащиться, волочиться)* өстерәлү, сөйрәлү, өстерәлеп бару (иләннән, җирдән).

**ВЕ'ЙНИК** *м. бот.*— чәчбай, тутык үлән.

**ВЕЙСМАНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — вейсманизм, вейсманчылык (биологиядә Дарвин тәгълиматына каршы реакцион идеалистик агым).

**ВЕК** *м. (мн.* века́) — **1.** гасыр, йөз, йөз ел; *двадцатый век* — егерменче гасыр, егерменче йөз; **2.** гомер; *на своём веку* — үз гомерендә; **3.** чор, дәвер; *каменный век* — таш чоры, таш дәвере; **4.** озак вакыт, озак вакытлар; күптән; *мы с тобой век не виделись* — без синең белән озак вакытлар күрешә алганыбыз юк; **5.** *в знач. нареч.* гомер буе, һәрвакыт, һаман; *век с тобой* — гомер буе синең белән; *век дома сидит* — һәрвакыт өйдә утыра. ◇ **Во веки или во веки веков** — гомер буена, гомергә, мәңгегә, гомер-гомергә. **На век, на веки или на веки вечные** — бөтенләйгә, мәңгегә. **В кои веки** — озак вакыттан соң, бик сирәк, гомердә бер. **От века** — мәңге. **Жить в чужой век** *простореч.* — бик озак яшәү. **Прожить аредовые веки** — бик озак яшәү. **Жить в веках** — мәңге яшәү. **Заедать чей-либо век** — гомерен кыскарту, гомерен ашау (кыерсытып).

**ВЕ'КО** *ср. (мн.* ве́ки) — күз кабагы.

**ВЕКОВА'ТЬ** *несов.*: **век вековать** — гомер буе яшәү; гомер буе тору, мәңге яшәү; *не век нам с тобой здесь вековать* — синең белән безгә монда мәңге торасы түгел.

**ВЕКОВЕ'ЧНЫЙ** *устар.* — бетмәс-төкәнмәс, мәңгелек, гомерлек; гомер-гомергә килгән; *вековечные распри* — гомер-гомергә килгән ызгышлар.

**ВЕКОВО'Й** — 1. *(многолетний)* күп яшәгән, бик карт; **2.** *(очень давний)* бик борынгы, борынгыдан килгән, мәңгелек.

**ВЕКОВУ'ХА, ВЕКОВУ'ША, ВЕКОВУ'ШКА** *ж. обл.* — сазаган кыз, утырып калган кыз, карт кыз.

**ВЕ'КСЕЛЬ** *м.* — **1.** вексель (куелган срок эчендә акча түләү турында бирелгән язма йөкләмә); **2.** *перен.* вәгъдәләр, йөкләмәләр; *правые социалисты любят давать векселя избирателям, но никогда по ним не платят* — уң социалистлар сайлаучыларга вәгъдәләр бирергә яраталар, ләкин аларны бервакытта да үтәмиләр.

**ВЕ'КСЕЛЬНЫЙ** — вексель...-ы; *вексельное право* — вексель хокукы.

**ВЕЛЕ'НЕВЫЙ: веленевая бумага** — яхшы эшләнгән, шома, тыгыз кәгазь.

**ВЕЛЕРЕЧИ'ВЫЙ** — **1.** *ирон. (высокопарный)* кабартылган, күпертелгән, тәкәллефле; **2.** *церк. устар. (многословный, красноречивый)* күп сүзле, күп сөйләргә яратучан; оста телле, матур сөйләүчән.

**ВЕЛЕ'ТЬ** *сов.* и *несов.* — боеру, кушу.

**ВЕЛИКА'Н** *м.* — алып, великан (гадәттән тыш зур гәүдәле кеше).

**ВЕЛИКА'НСКИЙ** — гаять зур, ифрат зур, великаннарча...; *великанский размах* — гаять зур колач.

**ВЕЛИКА'НША** *ж.* — к. великан.

**ВЕЛИ'КИЙ** — **1.** бөек; *Великая Октябрьская социалистическая революция* — Бөек Октябрь социалистик революциясе; **2.** *только кратк. формы.* зур, олы; *эта комната для вас велика* — бу бүлмә сезнең өчен зур. ◇ **У страха глаза велики** — курыкканга куш (күренә). **От мала до велика** — кечкенәсеннән алып олысынача, барысы да. **К великому счастью** — зур бәхеткә каршы. **Велика беда!** — исең киткән икән!

**ВЕЛИКОВА'ТЫЙ** *преимущ. кратк. формы; разг.* — бераз зуррак, беркадәр зуррак; *эти сапоги мне великоваты* — бу итек миңа бераз зуррак.

**ВЕЛИКОВО'ЗРА'СТНЫЙ** *устар.* — яше олаеп калган, яше үткән, олы яшьле.

**ВЗВОЛНО'ВАННЫЙ** —**1.** *(о море)* дулкынландырылган; **2.** *(встревоженный)* тынычсызландырылган, дулкынландырылган, тынычсыз хәлгә төшерелгән; **3.** *(выражающий волнение)* борчулы, борчылган.

**ВЗВОЛНОВА'ТЬ** *сов.*— к. волновать.

**ВЗВОЛНОВА'ТЬСЯ** *сов.*—к. волноваться.

**ВЗВОЛО'ЧЬ** *сов. разг.*— өстерәп мендерү, сөйрәп мендерү.

**ВЗВОЛО'ЧЬСЯ** *сов.* — өстерәлеп менү, сөйрәлеп менү, кыенлык белән менү, көчхәл белән менү.

пальтоны юу (яңа пальто сатып алу унае беләи интәшләренне сыйлау).

**ВЗБУДОРА'ЖИВАТЬ** *несов. разг.*— ыгы-зыгы куптару, аякка бастыру; борчу салу, тынычсызлау, ярсыту.

**ВЗБУДОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— ыгы-зыгы килү, аякка басу; борчылу, тынычсызлану, ярсу.

**ВЗБУДОРА'ЖИТЬ** *сов. разг.* — к. взбудораживать.

**ВЗБУДОРА'ЖИТЬСЯ** *сов. разг.*—к. взбудораживаться.

**ВЗБУНТОВА'ТЬ** *сов. разг.*— бунтка котырту, бунтка чакыру.

**ВЗБУНТОВА'ТЬСЯ** *сов.*—**1.** бунт чыгару, бунт күтәрү; **2.** *перен.* дулый башлау, котырына башлау.

**ВЗБУХА'ТЬ** *несов.*— к. взбухнуть.

**ВЗБУ'ХНУТЬ** *сов.*— күбенү, бүртү.

**ВЗБУ'ЧИТЬ** I. *сов. простореч.*—**1.** *(отколотить)* дөмбәсләү, пешерү, кыздыру (кыйнау, кыйнап ташлау мәгънәсендә); **2.** *(выругать)* сүгеп ташлау, орышу.

**ВЗБУ'ЧИТЬ** II *безл. сов. просторец.*— бүртү.

**ВЗБУ'ЧКА** *ж. просторец.*: **задать, дать или сделать взбучку**—арт сабагын укыту, кирәген бирү (**1.** кыйнау, кыйнап ташлау мәгънәсендә; **2.** каты шелтә бирү мәгънәсендә).

**ВЗБУШЕВА'ТЬ, ВЗБУШЕВА'ТЬСЯ** *сов.*— кинәт котырынып китү, давыллый башлау, дулый башлау; *река взбушевалась* — елга кинәт котырынып китте.

**ВЗВА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*—к. взвалить.

**ВЗВА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— 1. төялү, салыну; **2.** йөкләтелү, көчләп тагылу, мәҗбүр ителү (берәр эшкә); **3.** сылтану, аударылу (мәсәлән, гаеп).

**ВЗВАЛИ'ТЬ** *сов. разг.*—**1.** төяү, салу, күтәрү; *взвалить мешок на спину* — капчыкны аркага салу; **2.** *фам. (навязать)* йөкләү, көчләп тагу, мәҗбүр итү; **3.** *просторец. (взвести обвинение)* сылтау, аудару.

**ВЗВЕВА'ТЬ** *несов.*— к. взвеять.

**ВЗВЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— җил белән күтәрелү.

**ВЗВЕЗТИ'** *сов.*— к взвозить.

**ВЗВЕСЕЛИ'ТЬ** *сов. устар.* — күңелне ачу, күңелне күтәрү.

**ВЗВЕ'СИТЬ** *сов.*—1. үлчәү, үлчәп карау, авырлыгын үлчәү; 2. *перен.* исәпкә алу, һәр ягын уйлап, төрле яктан уйлап карау, бәя бирү; *взвесить все доводы* — барлык дәлилләрне исәпкә алу.

**ВЗВЕ'СИТЬСЯ** *сов.*— үлчәнү, үлчәнеп авырлыгыңны белү.

**ВЗВЕСТИ'** *сов.*—1. *(поднять вверх)* күтәрү, өскә күтәрү; **2.** сылтау, ташлау, аудару, ягу; *взвести на кого-н. клевету* — кемгә дә булса яла ягу.

**ВЗВЕСТИ'СЬ** *сов.*— күтәрелү, өскә күтәрелү, өскә юнәлү.

**ВЗВЕ'ШИВАТЬ** *несов.*— к. взвесить.

**ВЗВЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов.*—**1.** к. взвеситься; **2.** *страд.* үлчәнелү, авырлыгы үлчәнелү; **3.** *перен. страд.* исәпкә алыну, бәя бирелү, һәр ягы уйланып каралу.

**ВЗВЕ'ЯТЬ** *сов.*: **ветер взвеял пыль** — җил исеп тузан күтәрде.

**ВЗВИВА'ТЬ** *несов.*— к. взвить.

**ВЗВИВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. взвиться.

**ВЗВИ'ДЕТЬ** *сов.*: **не взвидеть света** — күз аллары караңгылану, күзгә бернәрсә дә күренмәү; *от боли он не взвидел света* — авыртудан аның күз аллары караңгыланды.

**ВЗВИЗГ** *м. разг.*— чинау, чинап җибәрү.

**ВЗВИ'ЗГИВАТЬ** *несов.* — чинау, чинап-чинап кую.

**ВЗВИ'ЗГНУТЬ** *сов.*— чинап җибәрү, чыелдап кую.

**ВЗВИНТИ'ТЬ** *сов.*—**1.** нык ярсыту, кабарту (мәсәлән, нервларны); **2.** чиксез күтәрү; *взвинтить цены* — бәяләрне чиксез күтәрү.

**ВЗВИ'НЧИВАТЬ** *несов.*— к. взвинтить.

**ВЗВИ'НЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— **1.** нык ярсытылу; **2.** чиксез күтәрелү.

**ВЗВИТЬ** *сов.*— бөтерә-бөтерә югары күтәрү, бөтереп югары күтәрү (мәсәлән, җил тузанны).

**ВЗВИ'ТЬСЯ** *сов.* — бөтерелә-бөтерелә югары күтәрелү, бөтерелеп югары күтәрелү.

**ВЗВИ'ХРИТЬ** *сов.*— өереп күтәрү, өереп-өереп күтәрү (мәсәлән, җил карны).

**ВЗВИХРИ'ТЬ** *сов. просторец.* — тырпайту, тузгыту, туздыру (чәчне).

**ВЗВИ'ХРИТЬСЯ** *сов.*— өермә булып күтәрелү.

**ВЗВИХРИ'ТЬСЯ** *сов. просторец.*— тырпаю, тузгу (чәч турында).

**ВЗВОД** I *м. воен.*— взвод (ротаның, батареяның, эскадронның бер бүлеге).

**ВЗВОД** II *м. спец.*— взвод (ату коралында затворның яки йозакның ударникны арткы хәлдә тотып тору өчен хезмәт итә торган бер детале).

**ВЗВОДИ'ТЬ** *несов.*— к. взвести.

**ВЗВОДИ'ТЬСЯ** *несов.*— к. взвестись.

**ВЗВО'ДНЫЙ** *воен.*—1. взвод...-ы; *взводный командир* — взвод командиры; **2.** *в знач. сущ.* взвод командиры.

**ВЗВОЗИ'ТЬ** *несов. редко* — югарыга ташу, югарыга илтү, югарыга мендерү.

**ВЗВОЗИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— югарыга ташылу, югарыга илтелү, югарыга мендерелү.

**ВЗВОЛА'КИВАТЬ** *несов. разг.*— к. взволочь.

**ВЗВОЛА'КИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— өстерәп мендерелү, сөйрәп мендерелү.

**ВЗВОЛНО'ВАННО** *нареч.*—борчылып, ярсып, дулкынланып.

**ВЗВОЛНО'ВАННЫЙ** —1. *(о море)* дулкынландырылган; 2. *(встревоженный)* тынычсызландырылган, дулкынландырылган, тынычсыз хәлгә төшерелгән; **3.** *(выражающий волнение)* борчулы, борчылган.

**ВЗВОЛНОВА'ТЬ** *сов.*— к. волновать.

**ВЗВОЛНОВА'ТЬСЯ** *сов.*—к. волноваться.

**ВЗВОЛО'ЧЬ** *сов. разг.*— өстерәп мендерү, сөйрәп мендерү.

**ВЗВОЛО'ЧЬСЯ** *сов.* — өстерәлеп менү, сөйрәлеп менү, кыенлык белән менү, көчхәл белән менү.

**ВЗДУТЬ** I *сов.* — **1.** күтәрү (өреп, исеп); *ветер вздул пыль* — җил (исеп) тузан күтәрде; **2.** *(разжечь)* кабызып җибәрү, яндырып җибәрү; **3.** *перен. (цену)* артык күтәрү, күтәреп җибәрү; 4. *безл.* шешенү, күбенү.

**ВЗДУТЬ** II *сов.*— тукмау, кирәген бирү, арт сабагын укыту (кыйнап ташлау).

**ВЗДУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(вспухнуть)* күбенү, бүртү, кабару, шешү, күбенеп чыгу, бүртеп чыгу, кабарып чыгу, шешеп чыгу; **2.** *(подняться кверху)* күтәрелү; **3.** *перен. (о ценах)* нык күтәрелү; 4. өрелү, киерелү; *паруса вздулись* — җилкәннәр өрелде (киерелде).

**ВЗДЫ'БИ'ТЬ** *сов. устар.* — үрә торгызу, арткы аякларына бастыру (атны).

**ВЗДЫ'БИ'ТЬСЯ** *сов.* — үрә тору, арткы аякларына басу (ат турында).

**ВЗДЫМА'ТЬ** *несов. устар.* — күтәрү, туздыру, кубару; *вздымать пыль* — тузан күтәрү, тузан туздыру.

**ВЗДЫМА'ТЬСЯ** *несов.*— күтәрелү.

**ВЗДЫХА'НИЕ** *ср. устар.* — **1.** к. вздыхать; **2.** *только мн.* мәхәббәт газаплары.

**ВЗДЫХА'ТЕЛЬ** *м. разг. ирон. устар.*— гыйшык тотучы, яратучы.

**ВЗДЫХА'ТЬ** *несов.*—**1.** *(испускать вздохи)* авыр сулау, ахылдау, көрсенү, уфылдау; **2.** *(тосковать)* сагыну, юксыну, ямансылау, кайгыру; **3.** *(быть влюблённым)* гыйшык утында яну, сөю, ярату.

**ВЗИМА'ТЬ** *несов.* — җыю, алу, түләтү (мәсәлән, налогны, суд расходларын).

**ВЗИМА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җыелу, алыну, түләтелү.

**ВЗИРА'ТЬ** *несов. устар.* — карау, карап тору. ◇ **Не взирая на кого-что** —...-га карамастан; *не взирая на хлопоты* — мәшәкатьләргә карамастан. **Не взирая на лица** — кемнең кем булуына карамастан.

**ВЗЛА'МЫВАТЬ** *несов.*— к. взломать.

**ВЗЛА'МЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— ватып ачылу.

**ВЗЛА'ЯТЬСЯ** *сов. простореч.*— кычкырына башлау, сүгә башлау.

**ВЗЛЕЗА'ТЬ** *несов.*, **ВЗЛЕ'ЗТЬ** *сов.*— менү, күтәрелү.

**ВЗЛЕЛЕ'ЯТЬ** *сов.*— **1.** *(вырастить)* иркәләп үстерү, тәрбияләп үстерү; **2.** булдыру, тудыру; *взлелеять надежду* — өмет тудыру.

**ВЗЛЁТ** *м.* — очып күтәрелеш, очып менеш. ◇ **Творческий взлёт** — иҗади күтәрелеш.

**ВЗЛЕТА'ТЬ** *несов.*— к. взлететь.

**ВЗЛЕТЕ'ТЬ** *сов.* — **1.** очып менү, очып күтәрелү; *птица взлетела на дерево* — кош агачка очып менде; **2.** тиз генә йөгереп менү, очып менү, атылып менеп китү. ◇ **Взлететь на воздух** — **1.** *(о взрыве)* шартлау, күле күккә очу (шартлап); **2.** *перен. (о планах и т. п.)* җимерелү, юкка чыгу.

**ВЗЛОМ** *м.* — вату, җимерү, ватып ачу (бикләгәнне).

**ВЗЛОМА'ТЬ** *сов.* — **1.** вату, ватып ачу; *взломать лёд* —боз вату; *взломать дверь*— ишекне ватып ачу; **2.** *воен.* җимерү, вату; *взломать оборону противника* — дошманның оборонасын җимерү.

**ВЗЛО'МЩИК** *м.*— ватып урлаучы карак.

**ВЗЛОХМА'ТИТЬ** *сов.*— тырпайту, тузгыту, чуалту.

**ВЗЛОХМА'ТИТЬСЯ** *сов.*— тырпаю, тузгу, чуалу.

**ВЗЛОХМА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. взлохматить.

**ВЗЛОХМА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— к. взлохматиться.

**ВЗЛУПЦЕВА'ТЬ, ВЗЛУПЦОВА'ТЬ** *сов. простореч.*— тукмаклап ташлау, кирәген бирү (кыйнап ташлау).

**ВЗЛЮБИ'ТЬ** *сов.:* не **взлюби́ть** — күрә алмау, яратмау.

**ВЗМА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— к. взмолиться.

**ВЗМА'НИВАТЬ** *несов.*— к. взманить.

**ВЗМА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— теләк уятылу, һәвәсләндерелү, дәртләндерелү.

**ВЗМАНИ'ТЬ** *сов. разг.*— теләк уяту, һәвәсләндерү, дәртләндерү, дәрт кертү.

**ВЗМА'ХИВАТЬ** *несов.*— селтәү, җилпү.

**ВЗМАХНУ'ТЬ** *сов.*— селтәп кую, җилпеп кую (мәсәлән, канатларны, кулны).

**ВЗМА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. взмочить.

**ВЗМА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чылатылу, юешләтелү.

**ВЗМА'ЩИВАТЬ** *несов. разг.* — к. взмостить.

**ВЗМА'ЩИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. взмоститься; **2.** *страд.* мендереп урнаштырылу.

**ВЗМЕСТИ'** *сов. устар.*— к. взметать.

**ВЗМЁТ** *м. обл. с.-х.*— сөрү, күтәрү; *взмёт пара* — пар күтәрү.

**ВЗМЕТА'ТЬ** *несов. устар.*— күтәрү, туздыру (мәсәлән, тузанны).

**ВЗМЕТНУ'ТЬ** *сов.*— селтәп җибәрү, җилпеп җибәрү; чөеп җибәрү. ◇ **Взметнуть взором** — күзне сирпеп алу. **Взметнуть брови** — каш сикертеп кую.

**ВЗМЕТНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — **1.** *(выброситься кверху)* ыргылып чыгу, күтәрелү; **2.** *устар. (наброситься с гневом)* ачуланып ташлану, ярсып ташлану.

**ВЗМОКА'ТЬ** *несов.*, **ВЗМО'КНУТЬ** *сов. разг.*— юешләнү, чылану.

**ВЗМОЛИ'ТЬ** *сов.*— үтенеп сорау, ялынып сорау, ялварып сорау, инәлеп сорау.

**ВЗМОЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ялына башлау, ялвара башлау, ялынып сорый башлау, инәлеп сорый башлау.

**ВЗМО'РЬЕ** *ср.*— диңгез буе.

**ВЗМОСТИ'ТЬ** *сов. разг.* — мендереп урнаштыру.

**ВЗМОСТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— менеп урнашу.

**ВЗМОЧИ'ТЬ** *сов. обл.*— чылату.

**ВЗМУТИ'ТЬ** *сов.*— **1.** болгату, болганчыкландыру; **2.** *перен. простореч.* борчу, тынычсызлау, тынычлыгын бозу.

**ВЗМУТИ'ТЬСЯ** *сов.* — болгану, болганчыклану.

**ВЗМУ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. взмутить.

**ВЗМЫВ** *м.*— кинәт күтәрелеш, җилпенеш; *взмывы волн* — дулкыннарның кинәт күтәрелеше, җилпенеше.

**ВЗМЫВА'ТЬ** *несов.*— к. взмыть.

**ВЗМЫ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. взмылить.

**ВЗМЫ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— к. взмылиться.
**ВЗМЫ'ЛИТЬ** *сов.*— **1.** *(сделать мыльным)* сабынлау, сабын күбеге белән каплау; **2.** *(о лошади)* күбекләндерү, күбеккә батыру.
**ВЗМЫ'ЛИТЬСЯ** *сов.* — **1.** сабынлану, сабын күбеге белән каплану; **2.** *(о лошади)* күбекләнү, күбеккә бату.
**ВЗМЫТЬ** *сов.* — очып күтәрелеп китү, югарыга күтәрелеп китү (кошлар, самолётлар һ. б. турында).
**ВЗНЕСТИ'** *сов.*— к. вносить.
**ВЗНЕСТИ'СЬ** *сов.*— к. взноситься.
**ВЗНОС** *м.* — взнос, түләм; *очередной взнос* — чираттагы взнос (түләм).
**ВЗНОСИ'ТЬ** *несов.*— **1.** *простореч. (вносить плату)* түләү, түләм кертү, взнос кертү; **2.** *устар. (переносить наверх)* өскә күчерү; **3.** *перен. устар.* карамагына тапшыру (эшне, докладны); **4.** *перен. поэт. устар.* олылау, югары күтәрү.
**ВЗНОСИ'ТЬСЯ** *несов.*— югары күтәрелү.
**ВЗНУЗДА'ТЬ** *сов.* — **1.** *(коня)* авызлыклау, авызлык кидерү; **2.** *перен. (подчинить себе)* буйсындыру, тыю, авызлыклау.
**ВЗНУ'ЗДЫВАТЬ** *несов.*— к. взнуздать.
**ВЗНУ'ЗДЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— авызлыклану, авызлык кидерелү.
**ВЗОБРА'ТЬСЯ** *сов.*— к. взбираться.
**ВЗОГНА'ТЬ** *сов.*— к. взгонять.
**ВЗОЙТИ'** *сов.* — **1.** *(на что-н. высокое)* менү, күтәрелү; ашу; **2.** *(о небесных светилах)* калку, чыгу, күтәрелү; **3.** *(прорасти)* шыту, шытып чыгу, тишелү, үсеп чыгу; **4.** *(о тесте)* кабару, күтәрелү; **5.** *простореч. (войти)* керү; **6.** *простореч. (быть впору)* сыю, ярау, таман булу (кием, аяк киеме турында). ◇ **Взойти на ум** *простореч.* — башка килү, искә төшү (берәр фикер турында).
**ВЗОПРЕ'ТЬ** *сов. простореч.*— тиргә бату, шабыр тиргә бату.
**ВЗОР** *м.*— **1.** караш, күз карашы; **2.** *перен. (глаза)* күз(ләр); **3.** *только мн.* игътибар, дикъкать, кызыксыну; *взоры всей Европы были прикованы к этим событиям* — бөтен Европаның игътибары бу вакыйгаларга юнәлгән иде. ◇ **Вперить взор** — текәлеп карау. **Потупить взор** — аска карау (оялудан).
**ВЗОРВА'ТЬ** *сов.*— шартлату, шартлатып күтәртү, шартлатып җимерү. ◇ **Его взорвали резкие слова товарища** — иптәшенең кискен сүзләреннән ул шартлый язды (бик каты ачуы килде).
**ВЗОРВА'ТЬСЯ** *сов.* — шартлау, шартлап ярылу, шартлап җимерелү.
**ВЗРА'ИВАТЬСЯ** *несов. спец.* — к. взроиться.
**ВЗРАСТА'ТЬ** *несов.*— к. взрасти.
**ВЗРАСТИ'** *сов.*— үсеп җитү.
**ВЗРАСТИ'ТЬ** *сов.* — карап үстерү, тәрбияләп үстерү.
**ВЗРА'ЩИВАТЬ** *несов.*— к. взрастить.
**ВЗРА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— карап үстерелү; тәрбияләп үстерелү.
**ВЗРЕВЕ'ТЬ** *сов.*—1. акырып җибәрү, үкереп җибәрү; *лев взревел* — арыслан үкереп җибәрде; **2.** *перен.* үкерә башлау; *взревели моторы* — моторлар үкерә башлады.

**ВЗРЕВНОВА'ТЬ** *сов. устар.* — көнләшә башлау.
**ВЗРЕЗ** *м.* — **1.** *(действие)* к. взрезать; **2.** киселгән урын.
**ВЗРЕ'ЗАТЬ** *сов.*— кисеп карау, яру.
**ВЗРЕЗА'ТЬ** *несов.*— к. взрезать.
**ВЗРЕЗА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кисеп каралу.
**ВЗРЕ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. взрезать.
**ВЗРЕ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. взрезаться.
**ВЗРОИ'ТЬСЯ** *сов. спец.*— күч (ил) булып күтәрелү (бал кортлары турында).
**ВЗРОСЛЕ'ТЬ** *несов.* — олыгаю, олыгая бару.
**ВЗРО'СЛЫЙ** — **1.** олы, буйга җиткән, үсеп җиткән; **2.** *в знач. сущ.* олы, зур; *дети ушли, а взрослые остались дома* — балалар киттеләр, ә зурлар өйдә калдылар.
**ВЗРЫВ** *м.*— **1.** шартлау, шартлап ярылу, шартлату; *взрыв бомбы* — бомба шартлау; *взрыв моста* — күперне шартлату; **2.** гөрелте; *революционный взрыв* — революция гөрелтесе; **3.** *перен. филос.* шартлау; *переход от старого качества к новому путём взрыва* — иске сыйфаттан яңа сыйфатка шартлау юлы белән күчү. ◇ **Взрыв рукоплесканий** — көчле кул чабулар.
**ВЗРЫВА'ТЕЛЬ** *м.*— шартлаткыч.
**ВЗРЫВА'ТЬ** I *несов.*— к. взорвать.
**ВЗРЫВА'ТЬ** II *несов.*— к. взрыть.
**ВЗРЫВА'ТЬСЯ** I *несов.* — **1.** шартлау, шартлап ярылу; **2.** *страд.* шартлатылу.
**ВЗРЫВА'ТЬСЯ** II *несов.* — казылу, йомшартылу (мәсәлән, туфрак).
**ВЗРЫВНО'Й** I *спец.* — шартлату...-ы, шартлау...-ы; шартлата торган; *взрывные работы* — шартлату эшләре; *взрывная волна* — шартлау дулкыны; *взрывной снаряд*— шартлата торган снаряд.
**ВЗРЫВНО'Й** II, **ВЗРЫ'ВНЫЙ** *лингв.* — шартлаулы; *взрывные звуки* — шартлаулы авазлар.
**ВЗРЫВЧА'ТКА** *ж.*— шартлагыч матдә.
**ВЗРЫ'ВЧАТОСТЬ** *ж. мн.* нет— шартлаучанлык.
**ВЗРЫ'ВЧАТЫЙ** — шартлаучан, шартлый торган.
**ВЗРЫ'ВЩИК** *м.*— шартлатучы (эшче).
**ВЗРЫТЬ** *сов.* — казу, йомшарту, казып йомшарту (җирне).
**ВЗРЫХЛИ'ТЬ** *сов.*— йомшарту, йомшартып күпертү (туфракны).
**ВЗРЫХЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. взрыхлить.
**ВЗРЫХЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — йомшартылу, йомшартып күпертелү.
**ВЗРЯБИ'ТЬ** *сов.*— шадралату (су өстен).
**ВЗРЯБИ'ТЬСЯ** *сов.* — шадралану (су өсте турында).
**ВЗЪЕДА'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. взъесться.
**ВЗЪЕЗЖА'ТЬ** *несов.* — (берәр нәрсәгә утырып) менү, күтәрелү.
**ВЗЪЕРЕПЕ'НИТЬСЯ** *сов. простореч.* — ачуланып киреләнү, ачуланып тискәреләнү.
**ВЗЪЕРО'ШИВАТЬ** *несов. разг.*— к. взъерошить.

**ВЗЪЕРО'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. взъерошиться; 2. *страд.* тырпайтылу, тузгытылу, кабартылу.

**ВЗЪЕРО'ШИТЬ** *сов. разг.* — тузгыту, тырпайту, кабарту.

**ВЗЪЕРО'ШИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. тырпаю, тузгу, кабару; 2. *перен.* ачулану, кабарыну.

**ВЗЪЕ'ХАТЬ** *сов.*— к. въезжать.

**ВЗЪЯРИ'ТЬСЯ** *сов. устар.* — кызып китү, ачу кабару, ярсу.

**ВЗЫВА'ТЬ** *несов.* — 1. ялынып сорау, үтенеп сорау, инәлеп сорау; *взывать о помощи* — ялынып ярдәм сорау; 2. чакыру, өндәү; *взывать о справедливости* — гаделлеккә өндәү.

**ВЗЫГРА'ТЬ** *сов.* — 1. шаяра башлау, уйный-көлә башлау; 2. *перен.* хәрәкәткә килү, котырынып китү (мәсәлән, дингез). ◇ **Взыграла душа** — бик нык шатландым.

**ВЗЫГРА'ТЬСЯ** *сов.*— к. взыграть.

**ВЗЫСКА'НИЕ** *ср.*— 1. түләтү (бурычны, штрафны); түләтелгән акча; 2. *(наказание)* шелтә, җәза, взыскание.

**ВЗЫСКА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — таләпчәнлек, таләп итүчәнлек, таләпчән булу.

**ВЗЫСКА'ТЕЛЬНЫЙ** — таләпчән, таләп итүчән.

**ВЗЫСКА'ТЬ** *сов.*— 1. түләтү; 2. *(наказать)* җавапка тарту, шелтәләү. ◇ **Не взыщи(те)** — гаепкә алма(гыз).

**ВЗЫСКА'ТЬСЯ** *сов. устар.* — тырышып эзли башлау.

**ВЗЫ'СКИВАТЬ** *несов.*— к. взыскать.

**ВЗЫ'СКИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. түләтелү; 2. җавапка тартылу.

**ВЗЯ'ТКА** *ж.*— 1. *(подкуп)* взятка, ришвәт; 2. *(в карточной игре)* взятка; 3. *обл.* к. взяток. ◇ **Взятки гладки** — сорап та торма, барыбер ала алмассың; бернәрсәсен дә ала алмассың.

**ВЗЯ'ТОК** *м.*— табыш (бал кортларының билгеле вакыт эчендә җыйган балы).

**ВЗЯ'ТОЧНИК** *м.*, **ВЗЯ'ТОЧНИЦА** *ж.* — взяткачы, взятка алучы, ришвәтче, ришвәт алучы.

**ВЗЯ'ТОЧНИЧАТЬ** *несов. разг.* — взятка алу, взятка алу белән шөгыльләнү.

**ВЗЯ'ТОЧНИЧЕСКИЙ** — взятка алу ...-ы; *взяточнические привычки* — взятка алу гадәтләре.

**ВЗЯ'ТОЧНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — взятка алу, взятка алучанлык, взятка алу гадәте.

**ВЗЯТЬ** *сов.* — 1. алу; 2. тоту; *взять за ру́ку* — кулдан тоту; 3. *(арестовать)* кулга алу; 4. алдыру; *взять смелостью* — кыюлык белән алдыру. ◇ **Возьми влево** — сулга тот. **Чья взяла?** — кайсы як җинде (өстен чыкты)? **Наша взяла** — без җиңдек, безнең як җинде (өстен чыкты). **Ни дать, ни взять** — нәкъ үзе, суйган да каплаган. **Возьму да скажу** — тотармын да әйтермен. **А вы возьми да скажи ему?** — ә сез чынлап та аңа әйттегезме? Ә сез тоттыгыз да әйттегезме? **С чего ты взял?** — нигә син шулай дип уйлыйсың?

**ВЗЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тотыну; *взяться за перила* — култыксага тотыну; 2. тотыну, керешү; *взяться за работу* — эшкә тотыну (керешү); 3. алыну, булу; *они взялись помочь нам* — алар безгә ярдәм итәргә алындылар, алар безгә ярдәм итәргә булдылар. ◇ **Откуда взялась эта книга?** — бу китап кайдан килеп чыккан? **Откуда ни возьмись** — көтмәгәндә, һич тә уйламаганда; *откуда ни возьмись, навстречу моська им* — көтмәгәндә алар каршына мүчкәй килеп чыкты. **Взяться за ум** — акылга утыру (ялгышын аңлап).

**ВИАДУ'К** *м. архит.* — виадук (чокыр, тимер юл кебекләр өстеннән үтү өчен салынган күпер).

**ВИБРА'ТОР** *м. физ.* — вибратор (тирбәлешләрне, мәсәлән, электр дулкыннарын, тудыра һәм һавага җибәрә торган прибор).

**ВИБРА'ЦИЯ** *ж. физ.* — вибрация, тибрәнү, калтырау.

**ВИБРИ'РОВАТЬ** *несов.* — тибрәнү, калтырау.

**ВИГИ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *псих.*— сизгерлек (дикъкатьне яңа алынган тәэсирләргә туплау сәләте).

**ВИГО'НЕВЫЙ** — вигонь...-ы; *вигоневая шерсть* — вигонь йоны.

**ВИГО'НЬ** *ж. текст.* — вигонь (1. *зоол.* Көньяк Америкада сарык зурлыгындагы күшәүче бер хайван; 2. *спец.* тукыма сорты).

**ВИД** I *м.* — 1. күренеш; *вид моста издалека* — күпернең ерактан күренеше; *плачевный тут представился нам вид* — безнең күз алдыбызга аянычбер күренеш килеп басты; 2. *(внешность, наружность человека)* кыяфәт, килбәт, килеш-килбәт; 3. *только мн.* планнар, ниятләр; *виды на будущее* — киләчәккә планнар, ниятләр. ◇ **Под видом чего-л.**—... дигән булып, ...дигән сылтау белән, ...-га салышып; *под видом болезни* — авырыйм дигән булып (авырыйм дигән сылтау белән). **В каком-либо виде** — хәлдә, килеш, көе; *я посылала Вам свои рассказы в неисправленном виде* — мин Сезгә хикәяләремне төзәтелмәгән хәлдә (килеш) җибәргән идем. **Иметь в виду** — 1. күздә тоту; *я имею в виду вчерашний случай* — мин кичәге вакыйганы күздә тотам; 2. истә тоту, онытмау; *он обещал иметь меня в виду в случае вакансии* — вакансия була калса, ул мине онытмаска вәгъдә бирде. **Для вида** — күз буяу өчен (чынлыкны яшерү өчен). **Делать вид** — ...-ган булып кылану, ...-ган булып утыру, ...-ганга салыну,...-ганга салышу; *делает вид, что пишет*—язган булып кылана. **Делать вид, что не ...**— ...-мәмешкә салыну,...-мәмешкә салышу; *делает вид, что не видит* — күрмәмешкә салыша. **Поставить на вид** — кисәтү, кисәтү ясау. **Не подавать виду** — сер бирмәү, сиздермәү. **Упустить из вида** или **из виду** — оныту, хәтердән чыгару. **Вид на жительство** *устар.* — паспорт. **Ни под каким видом** — һичбер, һичбер хәлдә. **Потерять из виду** — күздән югалту. **Он видал виды** — ул күпне күргән, ул төрлесен күргән, дөньяның ачы-

сын-төчесен татыган. **Иметь виды** — исәп тоту. **Виды на урожай** — игеннәрнең торышы.

**ВИД** II *м. науч.* — **1.** *филос., биол.* төр; **2.** *лингв.* күренеш (фигыль күренеше).

**ВИДА'ЛЫЙ** *обл. разг.* — күпне күргән.

**ВИДА'ЛЬЩИНА** *ж. мн.* нет, *обл.* — гади вакыйга, гади күренеш.

**ВИДА'ТЬ** I *несов. разг.* — күрү; *я не видал его со вчерашнего дня* — мин аны кичәдән бирле күргәнем юк. ◇ **Видал?** — күрденме? аңладыңмы? сизденме?

**ВИДА'ТЬ** II — **1.** *в знач. безл. сказ. простореч.* күренә; *парохода еще не видать* — пароход әле күренми; **2.** *ввод. сл.* ахры, күрәсең; *к ночи, видать, опять туман сядет* — төнгә таба тагын томан төшәр, ахры.

**ВИДА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — очрашу, күрешү; *они видаются часто* — алар еш очрашалар.

**ВИ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — күрү сәләте, күрү мөмкинлеге; *видение на расстоянии* — ерактан күрү сәләте, ерактан күрү мөмкинлеге.

**ВИДЕ'НИЕ** *ср.* — күз алдына килгән нәрсә, хыял.

**ВИ'ДЕТЬ** *несов.* — **1.** *(воспринимать зрением)* күрү; **2.** аңлау, сизү, күрү; *теперь-то я вижу, что он прав* — хәзер инде мин аның хаклы икәнлеген аңлыйм. ◇ **Видишь, видите** или **видишь ли, видите ли** — беләсеңме, беләсезме. **Видеть насквозь** *кого-н.* — кемне дә булса яхшы белү, үтәдән-үтә күрү. **Как видите** — күрәсез (бит), күргәнегезчә. **Видеть в розовом свете** — яхшы якларны гына күрү.

**ВИ'ДЕТЬСЯ** *несов.* — **1.** *(встречаться)* күрешү, очрашу; **2.** күренү, күренеп тору; *ему уже видится полный успех дела* — аңа инде эшнең тәмам уңышлы булачагы күренеп тора. ◇ **Ему виделся сон** — ул төш күргән, аның төшенә кергән. **Ему виделось во сне** — ул төшендә күргән, аның төшенә кергән. **Как видится** *ввод. сл. простореч.* — күрәсең, ахры; *как видится, весна будет ранняя* — яз иртә килер, ахры.

**ВИ'ДИМО** — **1.** *нареч.* тыштан караганда; *в инкубационный период болезни в видимо здоровом организме происходит размножение микроба* — авыруның инкубацион чорында тыштан караганда сәламәт булып күренгән организмда микробның үрчүе дәвам итә; **2.** *нареч. устар.* сизелерлек булып, ап-ачык булып; *в лице её видимо отражалась недоверчивость* — аның йөзендә ышанмау билгесе сизелерлек булып чагылып тора иде; **3.** *ввод. сл.* күрәсең, ахры, булса кирәк, мөгаен; *видимо, он чем-то был рассержен* — аның нәрсәгәдер ачуы килгән иде булса кирәк.

**ВИ'ДИМО-НЕВИ'ДИМО** *нареч. разг.* — чиксез күп, хисапсыз күп, иксез-чиксез, исәпсез-хисапсыз, чамасыз.

**ВИ'ДИМОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** күрү мөмкинлеге, күренүчәнлек; *в ясную погоду видимость лучше* — аяз көнне күрү мөмкинлеге яхшырак; **2.** тышкы күренеш. ◇ **Для видимости** — күз буяу өчен. **Это только одна видимость** — бу тик күз буяу гына.

**ВИ'ДИМЫЙ** — **1.** күренә торган; **2.** ачыктан-ачык, күренеп тора торган; *нет никакой видимой причины* — күренеп торган бернинди сәбәп тә юк.

**ВИДНЕ'ТЬСЯ** *несов.* — күренү, күренеп тору.

**ВИ'ДНО** — **1.** *безл. в знач. сказ.* күренә, күренеп тора; *отсюда всю деревню видно* — моннан бөтен авыл күренеп тора; **2.** *ввод. сл.* күрәсең, булса кирәк, ахры; *он, видно, любит поспать* — ул йокларга ярата булса кирәк.

**ВИ'ДНЫЙ** — **1.** күренә торган; **2.** *(значительный, важный)* күренекле, зур дәрәҗәле; **3.** *(статный, осанистый)* мәһабәт, мәһабәт гәүдәле.

**ВИДОВО'Й** — **1.** *лингв.* күренеш...-ы; *видовое понятие* — күренеш төшенчәсе; **2.** *филос. биол.* төр...-ы; *видовые признаки* — төр билгеләре. ◇ **Видовой фильм** — табигать күренешләрен күрсәтә торган фильм.

**ВИДОИЗМЕНЕ'НИЕ** *ср.* — **1.** к. видоизменять; **2.** төр, вариант; *плуг — усовершенствованное видоизменение сохи* — сабан — суканың камилләштерелгән бер төре.

**ВИДОИЗМЕНИ'ТЬ** *сов.* — к. видоизменять.

**ВИДОИЗМЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. видоизменяться.

**ВИДОИЗМЕНЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет — үзгәрүчәнлек, үзгәрүгә сәләтлелек.

**ВИДОИЗМЕНЯ'ТЬ** *несов.* — үзгәртү, үзгәреш кертү.

**ВИДОИЗМЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** үзгәрү, үзгәреш керү; **2.** *страд.* үзгәртелү, үзгәреш кертелү.

**ВИ'ДЫВАТЬ** *многокр. разг.* — күргәләү, күргән булу; *видывал ли ты что-н. подобное?* — менә охшаган берәр нәрсәне күргәнең бармы синең?

**ВИ'ЗА** *ж.* — **1.** *(на паспорте)* виза, рөхсәт (берәр дәүләткә керү, аннан китү яки аның территориясе аркылы үтү өчен хөкүмәт тарафыннан бирелә торган махсус рөхсәт); **2.** *(на документе)* виза, резолюция.

**ВИЗАВИ'** — **1.** *нареч.* кара-каршы; *они сидели визави* — алар кара-каршы утыралар иде; **2.** *м.* и *ж. нескл.* каршыдаш, каршыда утыручы; *мой визави* — минем каршыдашым (каршымда утыручым).

**ВИЗГ** *м.* — чинау тавышы, чыелдау тавышы, ачы тавыш.

**ВИЗГЛИ'ВО** *нареч.* — чинап, чыелдап.

**ВИЗГЛИ'ВЫЙ** — чыелдык, чинаучан.

**ВИЗГОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *разг.* — чыр-чу.

**ВИЗГУ'Н** *м.*, **ВИЗГУ'НЬЯ** *ж.* — чыелдаучы, чыелдык.

**ВИЗЖА'ТЬ** *несов. разг.* — чинау, чыелдау.

**ВИЗИ'ГА** *ж.* — визига, сырт сеңере (кызыл балыкта).

**ВИЗИ'Р** *м.* — визир (**1.** махсус аппаратларда төзәп карау өчен эшләнгән ярыклы пластинка; **2.** фотоаппаратка беркетелә

торган махсус прибор; **3.** самолётның билгеләнгән юлдан ни дәрәҗәдә читкә тайпылуын күрсәтә торган авиаприбор; **4.** геодезиядә визирлау инструментының бер өлеше).

**ВИЗИ'РОВАТЬ** I *сов.* и *несов. офиц.*— виза салу (паспортка һ. б.).

**ВИЗИ'РОВАТЬ** II *сов.* и *несов. спец.*— визирлау (карау сызыгын билгеле бер ноктага юнәлдерү, мәсәлән, геодезия коралы ярдәме белән).

**ВИЗИ'РОВАТЬСЯ** I *сов.* и *несов. страд.*— виза салыну.

**ВИЗИ'РОВАТЬСЯ** II *сов.* и *несов. страд.*— визирлану.

**ВИЗИ'РЬ** *м.*— вәзир (кайбер көнчыгыш илләрендә: министр).

**ВИЗИ'Т** *м.*— визит (**1.** рәсми рәвештә күрешә килү, күрешә бару; танышларга бару; **2.** врачның авырган кешенең өенә килүе).

**ВИЗИТЁР** *м. устар.*—визит белән килүче.

**ВИЗИ'ТКА** *ж.*— визитка (бер капламалы һәм түгәрәк чабулы кыска сюртук).

**ВИЗИ'ТНАЯ КА'РТОЧКА** — визит карточкасы (берәр кешенең исеме һәм фамилиясе язылган карточкасы; визит белән барганда үзен таныштыру өчен яки котлау җибәргәндә кулланыла).

**ВИ'КА** *ж. мн.* нет, *бот.*— вика, торна борчагы.

**ВИ'КОВЫЙ** — вика...-ы; *виковое поле* — вика кыры.

**ВИКО'НТ** *м.*— виконт (Франциядә һәм Англиядә баронлык белән графлык арасындагы дворянлык дәрәҗәсен белдерә торган титул).

**ВИКОНТЕ'ССА** *ж.*— виконт хатыны.

**ВИКСАТИ'Н** *м.*— виксатин (махсус состав белән капланган су үткәрми торган тукыма).

**ВИКТОРИ'НА** *ж.*— викторина (нинди дә булса бер темага караган сорауларга җавап бирүдән гыйбарәт уен).

**ВИКТО'РИЯ** I *ж. мн.* нет — виктория (җиләк).

**ВИКТО'РИЯ** II *ж. мн.* нет, *устар.*— җиңү (борынгы Рим мифологиясендә җиңү алласы).

**ВИ'ЛКА** *ж.*— **1.** чәнечке; **2.** вилка (**а.** шахматта ике яки берничә фигураның бер үк вакытта бер пешканың яки фигураның һөҗүме астында торуы; **б.** *воен.* снарядларның цельгә барып җитмәүләре һәм аннан узып китүләре арасындагы ара).

**ВИ'ЛЛА** *ж.*— вилла (шәһәр тышындагы бай һәм зиннәтле дача).

**ВИЛО'К** *м.*— бер баш кәбестә.

**ВИЛООБРА'ЗНЫЙ** — сәнәксыман, сәнәккә охшаган, чатлы.

**ВИ'ЛОЧНЫЙ** — чәнечке...-ы; *вилочное производство* — чәнечке производствосы.

**ВИ'ЛЫ** *только мн.*— сәнәк. ◇ **Вилами на воде написано** — бозга язган; алмаган бия, тумаган колын.

**ВИЛЬНУ'ТЬ** *сов. однокр.*— **1.** болгап кую; селтәп кую; *собака вильнула хвостом* — эт койрыгын болгап куйды; **2.** *перен.* тиз генә читкә тайпылу, борылу.

**ВИЛЯ'ТЬ** *несов.*— **1.** болгау, селтәү; *собака виляет хвостом* — эт койрыгын болгый; **2.** аунаклау, әвеш-түеш килү; *колесо виляет* — тәгәрмәч аунаклый; **3.** *перен. разг. неодобр.* хәйләләү, туры җавап тан баш тарту.

**ВИНА'** *ж.*— **1.** *(провинность)* гаеп; **2.** *(причина)* сәбәп. ◇ **Ставить в вину** — гаепкә санау. **Загладить вину** — гаепне юу.

**ВИНЕГРЕ'Т** *м.*— **1.** *(холодное кушание)* винегрет (төрле яшелчәләрдән ясалган салкын аш); **2.** *(всякая всячина)* боламык, җыен юк-бар (нәрсәләр кушылмасы).

**ВИНИ'ТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ** — винительный падеж (предлогсыз кулланылган очракларда татар теленең төшем килешенә туры килә).

**ВИНИ'ТЬ** *несов.*— **1.** *(считать виноватым)* гаепләү, гаепле санау; **2.** *разг. (упрекать)* шелтәләү.

**ВИНИ'ТЬСЯ** *несов. устар.*— гаепне тану, үзен гаепле дип санау.

**ВИ'ННЫЙ** — аракы...-ы; *винный запах* — аракы исе. ◇ **Винная ягода** — инҗир (җимеше).

**ВИНО'** *ср.*— кызыл аракы, вино.

**ВИНОВА'Т!** (извините) — гафу итегез!

**ВИНОВА'ТО** *нареч.*— гаебен сизеп; оялып.

**ВИНОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — гаеплелек.

**ВИНОВА'ТЫЙ** — гаепле.

**ВИНО'ВНИК** *м.*, **ВИНО'ВНИЦА** *ж.*— сәбәпче; *виновник торжества* — тантананың сәбәпчесе (ягъни кем хөрмәтенә тантана эшләнсә, шул).

**ВИНО'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гаеплелек.

**ВИНО'ВНЫЙ** — гаепле.

**ВИНОГРА'Д** *м.*— виноград, йөзем (җимеше һәм агачы).

**ВИНОГРАДА'РСТВО** *ср. мн.* нет — виноград үстерү, виноград үстерүчелек.

**ВИНОГРА'ДАРЬ** *м.*— виноград үстерүче.

**ВИНОГРА'ДИНА** *ж.*— виноград җимеше (нең бер бөртеге).

**ВИНОГРА'ДНИК** *м.*— виноград бакчасы.

**ВИНОГРА'ДНЫЙ**—1. виноград...-ы; *виноградная лоза* — виноград чыбыгы; **2.** виноград(тан) ясалган; *виноградное вино* — виноград аракысы (виноградтан ясалган аракы).

**ВИНОДЕ'Л** *м.*— аракы ясаучы.

**ВИНОДЕ'ЛИЕ** *ср. мн.* нет — аракы ясау.

**ВИНОДЕ'ЛЬЧЕСКИЙ** — аракы ясаучылык...-ы; *винодельческий район* — аракы ясаучылык районы.

**ВИНОКУ'Р** *м.*— аракы (спирт) куучы, аракы ясаучы.

**ВИНОКУРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — спирт куу, аракы куу, спирт ясау, аракы ясау.

**ВИНОКУ'РЕННЫЙ**—аракы...-ы, спирт...-ы; *винокуренный завод* — аракы заводы.

**ВИНОКУ'РНЫЙ** *тех.*— аракы куа торган, аракы ясый торган; *винокурный котёл* — аракы куа торган казан.

**ВИНОЧЕ'РПИЙ** *истор.*— **1.** виночерпий (борынгыда эчемлекләр белән идарә итүче һәм аларны кунакларга салып торучы);

2. *разг. шутл.* аракы салучы, аракы сонучы.

**ВИНТ** *м.*— 1. винт, шөреп; 2. *(для передвижения пароходов и т. п.)* винт. ◇ **Дать винта** *простореч.*— шылу, таю, сызу, качып китү, үкчә күтәрү, табан ялтырату.

**ВИ'НТИК** *м.*— 1. кечкенә винт, кечкенә шөреп; 2. *перен.* кисәк, бөтеннең кечкенә бер кисәге. ◇ **Винтиков** или **винтика нехватает (в голове)** — бер винтигы җитми; акыл өләшкәндә мич башында калган; кырыкка бер тулмаган; бер тактасы ким (аңгыра, акылга сай кеше турында әйтелә).

**ВИНТИ'ТЬ** *несов.*— бору, борып кертү, борып чыгару (винтны).

**ВИНТО'ВКА** *ж.*— винтовка (мылтык).

**ВИНТОВО'Й** — 1. винт...-ы; *винтовая шляпка* — винт шляпкасы; 2. винтлы; *винтовой пароход* — винтлы пароход; 3. винтсыман, бормалы; *винтовая лестница* — бормалы баскыч.

**ВИНТО'ВОЧНЫЙ** — винтовка...-ы; *винтовочные патроны* — винтовка патроннары.

**ВИНТО'М** *нареч.*— бормаланып, винт кебек.

**ВИНТООБРА'ЗНО** *нареч.* — борылыпборылып.

**ВИНТООБРА'ЗНЫЙ** — винтсыман, винтсымак, борма-борма, бормалы-сырмалы.

**ВИНЬЕ'ТКА** *ж.*— виньетка (китапта бүлек башына яки ахырына урнаштырыла торган кечкенә бизәк).

**ВИОЛОНЧЕЛИ'СТ** *м.*, **ВИОЛОНЧЕЛИ'СТКА** *ж.*— виолончельдә уйнаучы.

**ВИОЛОНЧЕ'ЛЬ** *ж.*— виолончель (скрипкадан зуррак 4 кыллы, смычоклы музыка коралы).

**ВИРА'Ж** *м.*— вираж (1. *ав. мор.* самолётның, пароходның янтаеп борылуы, туры сызык белән бара торган юлыннан авышуы; 2. *спорт.* узышу юлында яки кар тавында борылу урыны; 3. *фот.* фотография снимокларын юып төрле төскә кертү өчен кулланыла торган химик эретмә).

**ВИРТУО'З** *м.*— виртуоз, бик оста кеше (гадәттә үз һөнәрен бик яхшы белүче музыкант; гомумән нинди дә булса бер эшне бик оста башкаручы кешегә дә әйтелә).

**ВИРТУО'ЗНО** *нареч.* — виртуозларча, бик оста.

**ВИРТУО'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — виртуозлык, утә осталык.

**ВИРТУО'ЗНЫЙ** — виртуозларча...; бик оста; *виртуозное исполнение* — виртуозларча башкару.

**ВИ'РУС** *м. бактер.*— вирус (йогышлы авыру тудыручы гаять кечкенә микроб).

**ВИРШЕПЛЁТ** *м. разг. пренебр.*— талантсыз шагыйрь, шагыйрь кисәге.

**ВИРШЕПЛЁТСТВО** *ср. мн.* нет — начар шигырьләр язу.

**ВИ'РШИ** *только мн.*— 1. силлабик төзелешле шигырьләр (рус һәм украин әдәбиятында XVI—XVIII йөзләрдә кулланылган); 2. *пренебр.* начар шигырьләр.

**ВИ'СЕЛИЦА** *ж.*— дар агачы (кеше аса торган).

**ВИ'СЕЛЬНИК** *м.*— 1. *устар.* дарга асылган кеше; 2. *разг. бран.* асарга гына яраклы кеше.

**ВИСЕ'ТЬ** *несов.*— 1. эленеп тору, асылынып тору; *лампа висит над столом* — лампа өстәл турында эленеп тора; 2. салынып тору; *левая фалда висит* — сул чабуы салынып тора. ◇ **Висеть на волоске, на ниточке** — кыл өстендә тору (һәлакәткә, җимерелүгә якын булу). **Висеть в воздухе** — 1. *(находиться в неопределенном положении)* билгесез, ышанычсыз хәлдә булу; 2. *(быть необоснованным)* нигезләнмәгән булу. **Над ними висит опасность** — алар алдында куркыныч тора, аларны куркыныч көтә.

**ВИСКО'ЗА** *ж. мн.* нет— вискоза (1. ясалма ефәк хәзерләүдә кулланыла торган куе, үзле масса; 2. ясалма ефәк).

**ВИСКО'ЗНЫЙ** — 1. вискоза...-ы; *вискозное производство* — вискоза производствосы; 2. вискоза... , вискозадан ясалган; *вискозный шёлк* — вискоза(дан ясалган) ефәк.

**ВИСЛОУ'ХИЙ** — 1. *(о животных)* салынкы колаклы, салпы колаклы; 2. *(о человеке) перен.* ачык авыз, юләрсымак, аңгыра.

**ВИ'СНУТЬ** *несов.*— 1. салынып тору; салынып төшү; *волосы виснут на лоб* — чәче маңгаена салынып төшкән; 2. *перен. (льнут к кому-н.)* сырышу, сырышып яту.

**ВИСО'К** *м.* — 1. чигә; 2. *только мн.* чигә чәче.

**ВИСОКО'СНЫЙ: високосный год** — кәбисә ел (февраль ае 29 көннән килә торган ел).

**ВИСО'ЧНЫЙ** — чигә...-ы; *височная кость* — чигә сөяге.

**ВИСЮ'ЛЬКА** *ж. разг.*— тагылма, тагылма бизәк (бизәк өчен тагылган нәрсә).

**ВИСЯ'ЧИЙ** — 1. асылмалы, асмалы, эленеп тора торган; *висячая лампа* — асылмалы лампа; 2. салынкы, салынып төшкән.

**ВИТАМИ'Н** *м.*— витамин (1. кеше һәм хайваннар организмының нормаль яшәве өчен азыкта табылырга тиеш булган органик матдә; 2. шундый матдә кертеп эшләнгән дару).

**ВИТАМИНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— витаминлаштыру, витаминнарга баету.

**ВИТАМИ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — витаминлылык, витаминга байлык.

**ВИТАМИ'ННЫЙ** — витамин ...-ы; *витаминная лаборатория* — витамин лабораториясе.

**ВИТАМИ'НОВЫЙ** — витаминлык ...-ы; *витаминовые свойства* — витаминлык сыйфатлары.

**ВИТАМИНО'ЗНЫЙ** — витаминлы; *витаминозная пища* — витаминлы азык.

**ВИТА'ТЬ** *несов. книж.*: **витать в облаках, витать в мире мечтаний** — хыял дингезендә йөзү; **смерть витает над ним** — ул үлем алдында тора, аны үлем көтә.

**ВИТИЕВА'ТЫЙ** — башваткыч, кабарынкы, катлаулы (тел, стиль турында).

**ВИТИ'ЙСТВОВАТЬ** *несов. устар.* — ораторлык итү.

**ВИТИ'Я** *м. разг. устар.* — оратор, матур сөйләүче.

**ВИТО'Й** — **1.** үрелгән, ишелгән, үреп (ишеп) эшләнгән; **2.** бормалы; *витая лестница* — бормалы баскыч.

**ВИТРИ'НА** *ж.* — витрина (**1.** магазин тәрәзәсе эчендә товарларны күрсәтүгә кую өчен эшләнгән урын; **2.** күргәзмә әйберләре куела торган шкаф, ящик яки асылмалы такта).

**ВИТЬ** *несов.* — **1.** *(о верёвке)* үрү, ишү; **2.** *(о гнезде)* ясау. ◇ **Вить локоны** — чәч бөдрәләү.

**ВИ'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** *страд.* үрелү, ишелү; **2.** уралу, уралып үсү; *хмель вьётся по яблоне* — колмак алмагачка уралып үсә; **3.** *(завиваться)* бөдрәләнү; **4.** бөтерелеп күтәрелү, бөтерелеп очу; *вьётся пыль из-под копыт коня* — ат аяклары астыннан бөтерелеп тузан күтәрелә; **5.** *(извиваться, изгибаться)* бөгәрләнә-бөгәрләнә йөрү; бөгелә-сыгыла йөрү; **6.** *(о дороге, тропинке, реке)* бормалана-бормалана бару, бормалана-бормалана агу, сузылып китү; **7.** җилфердәү; *флаги вьются у ворот* — капкалар өстендә флаглар җилферди; **8.** чуалу, сырпаланып йөрү; *дети вьются около матери* — балалар аналары янында сырпаланып йөриләр (чуалалар); **9.** *(хитрить, заискивать)* ялагайлану, ярарга тырышу, тәлинкә тоту.

**ВИ'ТЮТЕНЬ** *м. зоол.* — эберчен, урман күгәрчене.

**ВИ'ТЯЗЬ** *м. устар.* — батыр сугышчы, баһадир егет.

**ВИХЛЯ'ВЫЙ, ВИХЛЯ'СТЫЙ** *простореч.* — килбәтсез.

**ВИХЛЯ'ТЬ, ВИХЛЯ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — **1.** *(о человеке)* алпан-тилпән йөрү, алпан-тилпән килү; *(о колесе)* аунаклау; **2.** *перен.* алдашу, хәйләләү, койрык болгау.

**ВИХО'Р** *м.* — тырпаеп тора торган чәч.

**ВИ'ХОРЬ** *м. простореч.* — к. вихрь.

**ВИХРА'СТЫЙ** — тырпайган чәчле.

**ВИХРЕВО'Й** — **1.** өермә...-ы; *вихревой столб* — өермә баганасы; **2.** өермәле; *вихревой ветер* — өермәле жил.

**ВИ'ХРЕМ** *нареч.* — бик тиз, кинәт, давыл кебек, бөтерелеп.

**ВИ'ХРИТЬ** *несов.* — бөтерү, өереп күтәрү.

**ВИ'ХРИТЬСЯ** *несов.* — бөтерелү, өермәләнү.

**ВИХРУ'Н** *м.* — бүрекле күгәрчен.

**ВИХРЬ** *м.* — **1.** өермә, давыл; **2.** *перен.* көчле хәрәкәт, өермә; *революция — вихрь, отбрасывающий назад всех ему сопротивляющихся* (К. Маркс) — революция — үзенә каршылык күрсәтә торган барлык кешеләрне артка этәреп ташлый торган көчле хәрәкәт ул.

**ВИЦЕ-...** — вице-... (консул, губернатор, президент кебек сүзләрнең алдына кушылып шул сүзләр белән аталучы зур дәрәҗәле кешеләрнең ярдәмчесен, урынбасарын аңлата торган кисәкчә); *вице-президент* — вице-президент (президент ярдәмчесе).

**ВИ'ШЕННИК** *м.* — чия бакчасы, чиялек.

**ВИ'ШЕННЫЙ** *простореч.* — чия...-ы; *вишенный сироп* — чия сиробы.

**ВИШНЁВКА** *ж.* — чия аракысы, чия настойкасы.

**ВИШНЁВЫЙ** — **1.** чия...-ы, чиядән ясалган; *вишнёвое варенье* — чия вареньесы; **2.** кара-кызыл, чия төсле; *вишнёвое платье* — кара-кызыл күлмәк, чия төсле күлмәк.

**ВИ'ШНЯ** *ж.* — чия (агачы һәм җимеше).

**ВИШНЯ'К** *м.* — к. вишенник.

**ВИШЬ** *частица простореч.* — кара син аны! менә син! *вишь, что выдумал!* — кара син аны, нәрсә уйлап чыгарган!

**ВКА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — кадап кую, чәнчеп кую.

**ВКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кадап куелу, чәнчеп куелу.

**ВКА'ПАТЬ** *сов.* — эчкә тамызу, тамызып салу.

**ВКА'ПЫВАТЬ** I *несов.* — к. вкопать.

**ВКА'ПЫВАТЬ** II *несов.* — к. вкапать.

**ВКА'ПЫВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — казып утыртылу.

**ВКА'ПЫВАТЬСЯ** II *несов. страд.* — эчкә тамызылу, тамызып салыну.

**ВКАРА'БКАТЬСЯ** *сов.* — **1.** үрмәләп керү; **2.** үрмәләп менү.

**ВКАРА'БКИВАТЬСЯ** *несов.* — к. вкарабкаться.

**ВКАТА'ТЬ** *сов.* — **1.** тәгәрәтеп кертү; **2.** *простореч. (внести в список)* исемлеккә язып кую, исемлеккә кертү.

**ВКАТИ'ТЬ** *сов.* — 1. тәгәрәтеп кертү; **2.** *(ударить)* кундыру, тондыру, бирие утыртү; **3.** *простореч. (внести в список)* исемлеккә язып кую, исемлеккә кертү; 4. *простореч. (стремительно въехать)* чаптырып килеп керү.

**ВКАТИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** тәгәрәп керү; **2.** к. вкатить 4; 3. *(стремительно войти)* йөгереп килеп керү.

**ВКА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. вкатить.

**ВКА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** тәгәрәп керү; 2. *страд.* тәгәрәтеп кертелү.

**ВКАЧА'ТЬ** *сов.* — суыртып кертү, качать итеп кертү (насос белән).

**ВКА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. вкачать.

**ВКА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — суыртып кертелү, качать итеп кертелү.

**ВКИДА'ТЬ** *сов.* — эчкә ыргыту, ыргытып кертү.

**ВКИ'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. вкидать.

**ВКИ'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — эчкә ыргытылу, ыргытып кертелү.

**ВКИ'НУТЬ** *сов.* — к. вкидать.

**ВКЛАД** *м.* — **1.** *фин. экон.* вклад, кертем, салынган акча; **2.** *перен.* казаныш, вклад; *ценный вклад в науку* — фән өчен кыйммәтле казаныш, фәнгә кыйммәтле вклад.

**ВКЛА'ДКА** *ж.* — **1.** к. вкладывать; **2.** *спец.* вкладка (китап яки газета эченә салынган аерым бит).

**ВКЛАДНО'Й** — **1.** вклад...-ы, акча кертү ...-ы; *вкладные операции* — вклад операцияләре, акча кертү операцияләре; **2.** эчкә

салынган; *вкладной лист в книге* — китап эченә салынган бит.

**ВКЛА'ДЧИК** *м.*, **ВКЛА'ДЧИЦА** *ж.* — вкладчы, вклад кертүче, акча салучы.

**ВКЛА'ДЫВАТЬ** *несов.*— к. вложить.

**ВКЛ'АДЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— салыну, кертелү, эчкә куелу.

**ВКЛА'ДЫШ** *м.* — вкладыш (1. машина эченә яки астына металлдан яки агачтан ясалып салынган берәр деталь; 2. китапка, дәфтәргә өстәп салынган аерым бит, вкладка).

**ВКЛАСТЬ** *сов., простореч.*— к. вложить.

**ВКЛЕ'ИВАТЬ** *несов.*— к. вклеить.

**ВКЛЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.*— к. вклеиться.

**ВКЛЕИ'ТЬ** *сов.*— эченә ябыштырып кую. ◇ **Вклеить слово** — сүз кыстыру.

**ВКЛЕИ'ТЬСЯ** *сов.* — эченә ябыштырып куелу, эченә ябыштырылу.

**ВКЛЕ'ЙКА** *ж.* — ябыштырма, вклейка (китап эченә ябыштырылган аерым бит, рәсем).

**ВКЛЕПА'ТЬ** *сов.*— **1.** клёпкалап кую (эченә); 2. *перен. простореч.* бәлагә кертү, бәлагә төшерү, бәлагә эләктерү.

**ВКЛЕПА'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** *тех.* клёпкалап куелу (эченә); **2.** *перен. простореч.* бәлагә эләгү.

**ВКЛЁПЫВАТЬ** *несов.*— к. вклепать.

**ВКЛЁПЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. вклепаться.

**ВКЛИ'НИВАТЬ** *несов.*— к. вклинить.

**ВКЛИ'НИВАТЬСЯ** *несов.* — к. вклиниться.

**ВКЛИНИ'ТЬ** *сов.* — 1. чөйләп кертү, очлап кертү; **2.** *перен.* кыстырып кую (сөйләшкәндә сүз кыстыру).

**ВКЛИНИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. очлаеп керү, очланып керү; **2.** *(вторгнуться)* ерып керү, ярып керү, бәреп керү, арага килеп керү.

**ВКЛЮЧА'ТЕЛЬ** *м.*— тоташтыргыч, включатель.

**ВКЛЮЧА'ТЬ** *несов.*— к. включить.

**ВКЛЮЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. включиться; **2.** *страд.* кертелү, катнаштырылу, тоташтырылу.

**ВКЛЮЧА'Я** *дееприч. в знач. предлога*— кертеп исәпләгәндә; *зрителей, включая детей, было до ста человек* — балаларны кертеп исәпләгәндә, йөзләп тамашачы бар иде.

**ВКЛЮЧИ'ТЕЛЬНО** *нареч.*— кертеп, эченә алып.

**ВКЛЮЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. *тех.* тоташтыру, тоташтырып кую; **2.** *(внести, ввести)* кертү, өстәү; **3.** кабызу, эшләтә башлау; *включить мотор* — моторны кабызу (эшләтә башлау).

**ВКЛЮЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** *тех.* тоташу; **2.** *перен.* катнашу, катнашып китү, кушылу.

**ВКОВА'ТЬ** *сов.*— чүкеп кертү.

**ВКО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. вковать.

**ВКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чүкеп кертелү.

**ВКОЛА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. вколотить.

**ВКОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кагып кертелү.

**ВКОЛОТИ'ТЬ** *сов.*— кагып кертү. ◇ **Вколотить в голову** — башына туку. **Вколотить в гроб** — гүргә кертү.

**ВКОЛО'ТЬ** *сов.*— кадап кую, чәнчеп кую.

**ВКОЛО'ТЬСЯ** *сов.*— кадалу, чәнчелү.

**ВКО'МКАТЬ** *сов.*— йомарлап тыгу.

**ВКОНЕ'Ц** *нареч.*— бөтенләй, тәмам.

**ВКО'ПАННЫЙ** — казып утыртылган. ◇ **Стоит как вкопанный** — баскан да каткан, катып калган.

**ВКОПА'ТЬ** *сов.*— казып утырту.

**ВКОПА'ТЬСЯ** *сов.*— казып утыртылу.

**ВКОРЕНИ'ТЬ** *сов.*— тамыр җәйдерү, ныгыту.

**ВКОРЕНИ'ТЬСЯ** *сов.*— тамыр җәю, ныгу.

**ВКОРЕНЯ'ТЬ** *несов.*— к. вкоренить.

**ВКОРЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. вкорениться.

**ВКОРОТКЕ'** *нареч. устар.* — **1.** *(в скором времени)* тиздән, тиз вакытта; **2.** *(вкратце)* кыскача.

**ВКОСИ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** чалгы белән чабачаба эчкә кереп китү; **2.** *перен.* чабуга күнегеп китү.

**ВКОСУ'Ю** *нареч. простореч.*— к. вкось.

**ВКОСЬ** *нареч.* — кыйгачлап, кыеклап, кыек итеп, чалыш.

**ВКП(б)** —ВКП(б) (Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) партиясе).

**ВКРА'ДЧИВО** *нареч.*—ялагайланып, юхаланып.

**ВКРА'ДЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — ялагайлык, юхалык, юмакайлык.

**ВКРА'ДЧИВЫЙ** — ялагай, юмакай, юха.

**ВКРА'ДЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. вкрасться.

**ВКРАПИ'ТЬ** *сов.*— **1.** бөркеп бөрчекләр ясау (мәсәлән, соры буяу өстенә ак буяу бөркеп); **2.** *перен.* кисәк-кисәк итеп урнаштыру, кертү.

**ВКРА'ПЛИВАТЬ** *несов.*— к. вкрапить.

**ВКРА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** *страд.* бөрчек-бөрчек итеп урнаштырылу; **2.** бөрчек-бөрчек булып урнашу.

**ВКРАПЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. вкрапить.

**ВКРАПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. вкрапливаться.

**ВКРА'СТЬСЯ** *сов.* — **1.** *(войти тайком)* сиздермичә килеп керү, посып, яшеренеп керү; **2.** китү; *в статью вкрались ошибки*— мәкаләдә хаталар киткән; **3.** *перен.* хәйләләп ... казану, ялагайланып ... казану; *вкрасться в доверие* — хәйләләп ышаныч казану.

**ВКРА'ТЦЕ** *нареч.*— кыскача, кыскартып.

**ВКРИВЬ** *нареч. разг.*— **1.** кыек, кыегаеп; *берёза растёт вкривь* — каен кыегаеп үсә; **2.** *перен.* бозып, ялгыш; *он всё понимает вкривь*—ул барысын да ялгыш аңлый. ◇ **Вкривь и вкось** — **1.** кыйшык-мыйшык; **2.** *перен.* юри бозып; *толковать вкривь и вкось* — юри бозып аңлату.

**ВКРУГ** *нареч.* и *предлог* — к. вокруг.

**ВКРУГОВУ'Ю** *нареч. простореч.*— **1.** әйләндереп, чолгап, тирәли әйләндереп; **2.** кулдан кулга.

**ВКРУТИ'ТЬ** *сов.*— 1. борып-борып кертү, бөтереп кертү; **2.** *перен. простореч.* ялганлау, ялганга ышандыру.

**ВКРУТИ'ТЬСЯ** *сов.*— бөтерелеп керү.

**ВКРУТУ'Ю** *нареч.* — каты итеп (пешерелгән йомырка турында).

**ВКРУ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. вкрутить.

**ВКРУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. вкрутиться; 2. *страд.* бөтереп кертелү.

**ВКУ'ПЕ** *нареч.* — бергәләп, берлектә, бергә.

**ВКУС** *м.* — 1. тәм; *горький вкус* — ачы тәм; *пробовать на вкус* — тәмен татып карау; 2. зәвык, вкус; кызыксыну, гадәт; ...-дан тәм табу; *вкус к поэзии* — поэзиядән тәм табу, поэзия белән кызыксыну; *у каждого свой вкус, кто любит дыню, а кто арбуз* — һәркемнең үзенә күрә вкусы була: берәү кавын ярата, берәү карбыз ярата (кем нәрсә тели бит: берәү кавын ярата, берәү карбыз ярата); 3. татым, ямь тойгысы; *человек со вкусом* — татымлы кеше; 4. стиль, вкус; *ваза в античном вкусе* — антик стильдә ясалган ваза. ◇ **Одеваться со вкусом** — киенә белеп киенү.

**ВКУСИ'ТЬ** *сов. устар.*— 1. татып карау, тәмен белү; 2. *перен.* тою, сизү.

**ВКУ'СНО** *нареч.*— тәмле итеп.

**ВКУ'СНЫЙ** — тәмле.

**ВКУСОВО'Й** — 1. тәм...; *вкусовое ощущение* — тәм сизү; 2. тәмләндергеч, тәм бирә торган, тәм кертә торган, тәмләндерә торган; *вкусовые вещества* — тәмләндергеч матдәләр.

**ВКУША'ТЬ** *несов.*— к. вкусить.

**ВЛА'ГА** *ж. мн.* нет — дым, юешлек.

**ВЛАГА'ЛИЩЕ** *ср.*— 1. *анат.* жинсә, аналык жинсәсе; 2. *бот.* жинсә; 3. *устар.* футляр, кыны.

**ВЛАГА'ТЬ** *несов.*— к. вложить.

**ВЛАГА'ТЬСЯ** *несов.*— к. вкладываться.

**ВЛАДА'ТЬ** *несов. обл.*— к. владеть.

**ВЛАДЕ'ЛЕЦ** *м.*, **ВЛАДЕ'ЛИЦА** *ж.* — хужа, ия, биләүче.

**ВЛАДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *(обладание)* биләү, ия булу, хужа булу; 2. *(собственность)* милек, биләмә; 3. жир, территория; *английские владения на Востоке* — Көнчыгышта Англия кул астындагы жирләр.

**ВЛАДЕ'ТЕЛЬ** *м.*, **ВЛАДЕ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— биләүче, хужалык итүче.

**ВЛАДЕ'ТЕЛЬНЫЙ** — хужалык итәргә хокуклы, хужалык итүче.

**ВЛАДЕ'ТЬ** *несов.*— 1. *(обладать чем-л.)* ия булу, хужа булу, ия булып тору; 2. *(держать в своей власти)* биләү, биләп тору, кулында тоту; 3. эш итә белү; *владеть оружием* — корал белән эш итә белү. ◇ **Владеть языком** — сөйләшә белү, сөйләшә алу. **Владеть руками, ногами и т. п.** — кулларны (аякларны һ. б.) эшләтә алу, хәрәкәт иттерә алу, йөртә алу. **Владеть голосом** — тавыштан файдалана белү (жырлаганда, сөйләгәндә). **Владеть собой, своими чувствами** — үзеңә хужа булу, үзеңне кулда тота белү (тыныч һәм салкын канлылык белән фикер йөртә белү, эш итә белү).

**ВЛАДЫ'КА** *м.* — 1. хакимлек итүче, боеручы, хужа, ия; 2. *церк.* архиерей.

**ВЛАДЫ'ЧЕСТВО** *ср.* — өстенлек, хакимлек, югары власть.

**ВЛАДЫ'ЧЕСТВОВАТЬ** *несов.* — өстенлек итү, хакимлек итү, идарә итү.

**ВЛАДЫ'ЧИЦА** *ж.* — 1. к. владыка 1; 2. *церк.* Мәрьям ана.

**ВЛАЖНЕ'ТЬ** *несов.*— дымлану, юешләнү.

**ВЛА'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — дымлылык, юешлек; дымлылык дәрәжәсе.

**ВЛА'ЖНЫЙ** — дымлы, юеш.

**ВЛА'МЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. вломиться.

**ВЛА'СТВОВАТЬ** *несов.* — 1. идарә итү, власть башында тору, хакимлек итү, өстенлек итү; 2. *устар.* үз-үзеңне тота белү; *учитесь властвовать собою* — үз-үзегезне тота белергә өйрәнегез.

**ВЛАСТЕЛИ'Н** *м.*— хакимлек итүче, властьиясе.

**ВЛАСТИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ВЛАСТИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— к. властелин.

**ВЛАСТИ'ТЕЛЬНО** *нареч.*— к. властно.

**ВЛАСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *устар.* — к. властный.

**ВЛАСТИ'ТЕЛЬСКИЙ** *устар.* — хакимлек итәргә яратучан, боерырга яратучан; буйсындыруга сәләтле.

**ВЛА'СТНО** *нареч.* — хакимнәрчә, власть няләренчә.

**ВЛА'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. боеручанлык, хакимчәнлек; 2. боерырга яратучанлык.

**ВЛА'СТНЫЙ** — 1. *(склонный властвовать)* хакимлек итәргә яратучан, боерырга яратучан; 2. буйсындырырга сәләтле, буйсындыручан; *властный взгляд* — буйсындыручан караш. ◇ **Он не властен распоряжаться в чужом деле** — аның чит кешеләр эшенә катнашырга хакы юк.

**ВЛАСТОЛЮ'БЕЦ** *м.* — власть сөюче, власть яратучы, властька омтылучы.

**ВЛАСТОЛЮБИ'ВО** *нареч.*— властька омтылып, власть яратып.

**ВЛАСТОЛЮБИ'ВЫЙ** — власть сөючән, власть яратучан, властька омтылучан.

**ВЛАСТОЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет — властька омтылу, власть сөю.

**ВЛАСТЬ** *ж.* — 1. власть; *Советская власть* — Советлар власте; 2. *(могущественное влияние)* көчле тәэсир, буйсындыргыч көч, өстенлек, хакимлек; 3. *только мн.* власть ияләре (кешеләре), начальниклар; *по предписанию военных властей* — хәрби власть ияләренең (начальникларының) кушуы буенча. ◇ **Во власти** *чьей что-л. сделать*— ихтыярында; *в его власти отказаться* — риза булмау аның ихтыярында.

**ВЛАСЯНИ'ЦА** *ж. церк.*— кылдан ясалган кием.

**ВЛАЧИ'ТЬ** *несов. церк. устар.*— өстерәү, сөйрәү, өстерәп алып бару. ◇ **Влачить жалкое существование** — фәкыйрьлектә яшәү, мохтажлыкта яшәү, бик авыр тормыш алып бару.

**ВЛАЧИ'ТЬСЯ** *несов. устар.* — өстерәлү, сөйрәлү; каңгырып йөрү.

**ВЛЕ'ВО** *нареч.*— сулга, сул якка; сулда, сул якта.

**ВЛЕЗА'ТЬ** *несов.*— к. влезть.

**ВЛЕЗТЬ** *сов.*— 1. менү; *влезть на дерево* — агач башына менү; 2. керү; *влезть в окно* — тәрәзәдән керү; 3. *просторeч.* этеп-

төртеп керү; кысыла-кысыла керү, тыкшынып керү; *влезть в трамвай* — трамвайга кысыла-кысыла керү; 4. *разг.* сыю, сыеп бетү; *все книги влезли в портфель* — китапларның барысы да портфельгә сыеп бетте. ◇ **Влезть в долги** — бурычка бату. **Влезть в душу** — 1. кемнең дә булса ышанычын казану, игътибарын үзенә тарту; 2. эчке серләрен белү.

**ВЛЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. эченә ябыштырып кую; 2. *перен. разг. фам.* кундыру, тондыру, чәпәү; *влепить пощёчину* — яңагына кундыру; 3. *школьн. арго (о плохой отметке)* чәпәү.

**ВЛЁТ** *м.* — 1. очып керү; 2. *простореч.* шелтә, орышу.

**ВЛЕТА'ТЬ** *несов.* — к. влететь.

**ВЛЕТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. очып керү; 2. *перен. разг. (вбежать)* атылып килеп керү; 3. *разг. вульг.* уңайсыз хәлдә калу, бәлагә юлыгу; 4. эләгү; *шалуну влетело* — шаян малайга эләкте (ягъни аны орыштылар).

**ВЛЕЧЕ'НИЕ** *ср.* — көчле теләк, дәрт, һәвәслек, омтылыш; *влечение к труду* — хезмәткә дәрт, хезмәткә омтылыш. ◇ **Сердечное влечение** — мәхәббәт, гыйшык.

**ВЛЕЧЬ** *несов.* — 1. *(тащить)* өстерәү, тарту; 2. *(привлекать)* тарту, җәлеп итү. ◇ **Влечь за собой** — сәбәп булу, китереп чыгару; *преступление влечёт за собой наказание* — җинаять җәзага сәбәп була.

**ВЛЕ'ЧЬСЯ** *несов.* — 1. өстерәлү, сөйрәлеп бару; 2. омтылу, дәртсенү.

**ВЛИВА'НИЕ** *ср.* — 1. к. влить; 2. *мед.* организмга дару җибәрү; 3. *мед.* организмга җибәрелә торган дару.

**ВЛИВА'ТЬ** *несов.* — к. влить.

**ВЛИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. влиться; 2. *(впадать)* кою (елгалар турында).

**ВЛИПА'ТЬ** *разг. вульг.* — к. влипнуть.

**ВЛИ'ПНУТЬ** *сов. разг. вульг.* — эләгү, кабу, килеп кабу (уңайсыз хәлгә төшү мәгънәсендә).

**ВЛИТЬ** *сов.* — 1. салу, кою (сыек әйберне берәр савыт эченә); 2. *перен.* кертү; *это влило в него бодрость* — бу аңа дәрт кертте. ◇ **Влить новые кадры в промышленность** — промышленностька яңа кадрлар бирү, кертү.

**ВЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. агып керү; 2. *перен.* өстәлү, кушылу; *в нашу организацию влились свежие силы* — безнең оешмага яңа көчләр өстәлде; 3. *перен.* туу, керү; *в меня влилась уверенность в успехе* — эшнең уңышлы булып чыгачагына миндә ышаныч туды.

**ВЛИЯ'НИЕ** *ср.* — 1. *(воздействие)* тәэсир, йогынты; 2. авторитет; *человек с большим влиянием* — зур авторитетлы кеше.

**ВЛИЯ'ТЕЛЬНЫЙ** — авторитетлы, сүзе үтүчән.

**ВЛИЯ'ТЬ** *несов.* — тәэсир итү, йогынты ясау.

**ВЛКСМ** (Всесоюзный Ленинский Коммунистический Союз Молодёжи) — ВЛКСМ (Бөтенсоюз Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзы).

**ВЛОЖЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *(действие)* эченә салу, эченә кую; 2. пакетка салынган әйбер. ◇ **Государство сделало миллиардные вложения в строительство** — дәүләт төзелешкә миллиардларча акча (капитал) кертте.

**ВЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. эченә салу, эченә салып кую; 2. кертү, салу; *вложить миллионы в промышленность* — промышленностька миллионнарча акча кертү. ◇ **Вложить всю душу в любимое дело** — сөйгән эшкә җан-тән белән бирелү.

**ВЛОМИ'ТЬСЯ** *сов.* — көчләп килеп керү, ватып-җимереп килеп керү.

**ВЛО'ПАТЬСЯ** *сов. разг. вульг.* — 1. *(попасться)* бәлагә эләгү, бәлагә тап булу, хур булу, килеп кабу; 2. *(влюбиться)* гашыйк булу.

**ВЛОСК** *нареч. простореч.* — 1. бөтенләй, тәмам; 2. *(о степени опьянения)* лаякыл.

**ВЛЮБИ'ТЬ** *сов.* — яраттыру, сөйдерү, гашыйк итү.

**ВЛЮБИ'ТЬСЯ** *сов.* — гашыйк булу, сөю.

**ВЛЮБЛЁННО** *нареч.* — яратып; сөеп, мәхәббәт күрсәтеп.

**ВЛЮБЛЁННЫЙ** — 1. гашыйк, гашыйк булган, гыйшык тоткан; 2. гашыйкларча ...; *влюблённый взгляд* — гашыйкларча карау. ◇ **Он влюблён в свою работу** — ул үз эшенә тәмам бирелгән, ул үз эшен бик ярата.

**ВЛЮБЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. влюбить.

**ВЛЮБЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. влюбиться.

**ВЛЮ'БЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тиз гашыйк булучанлык, еш гашыйк булучанлык.

**ВЛЮ'БЧИВЫЙ** *разг.* — тиз гашыйк булучан, еш гашыйк булучан.

**ВЛЯ'ПАТЬСЯ** *сов. разг. вульг.* — 1. барып бату, чап иттереп егылу (берәр юеш нәрсәгә); 2. уңайсыз хәлгә төшү, бәлагә эләгү.

**ВМА'ЗАТЬ** *сов.* — 1. кертеп сылап кую; 2. *простореч. вульг. (ударить)* ямау, кундыру, чәпәү.

**ВМА'ЗЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. вмазать.

**ВМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кертеп сылап куелу.

**ВМА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. вмотать.

**ВМЕНИ'ТЬ** *сов.*: **вменить в заслугу** — күрсәткән хезмәт дип исәпләү; **вменить в вину** — гаеп дип санау; **вменить в обязанность** — йөкләү, бурыч итеп кую.

**ВМЕНИ'ТЬСЯ** *сов.*: **вмениться в заслугу** — күрсәткән хезмәт дип исәпләнү; **вмениться в вину** — гаеп дип саналу; **вмениться в обязанность** — бурыч итеп куелу.

**ВМЕНЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет — акылында булу (үз эшләре өчен закон каршында үзе җавап бирерлек хәлдә булу).

**ВМЕНЯ'ЕМЫЙ** — акылы сау, акылы урынында (үз эшләре өчен закон каршында үзе җавап бирергә сәләтле).

**ВМЕНЯ'ТЬ** *несов.* — к. вменить.

**ВМЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. вмениться.

**ВМЁРТВУЮ** *нареч.* — суырып чыгармаслык итеп; *забить гвоздь вмёртвую* — ка-

дакны суырып чыгармаслык итеп кагып кую.

**ВМЕ'РУ** *нареч.*— тиешенчә.

**ВМЕСИ'ТЬ** *сов.* — кушып басу, изү (камырга бирәр нәрсә).

**ВМЕ'СТЕ** *нареч.* — 1. *(сообща)* бергә, бергәләп, берлектә; 2. *(одновременно)* бер үк вакытта, берьюлы. ◇ **Вместе с тем** — шуның белән бергә, шул ук вакытта. **Всё вместе взятое** — жыеп әйткәндә; бөтенесен бергә алганда.

**ВМЕСТИ'** *сов.*— себереп кертү.

**ВМЕСТИ'ЛИЩЕ** *ср.*—урын, савыт, резервуар (берәр нәрсәне, мәсәлән, ашлыкны, салып саклау урыны).

**ВМЕСТИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — сыешлылык.

**ВМЕСТИ'МЫЙ** — сыя ала торган.

**ВМЕСТИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет—сыйдырышлылык, сыйдырышлы булу.

**ВМЕСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — күп сыйдырышлы, иркен.

**ВМЕСТИ'ТЬ** *сов.*— к. вмещать.

**ВМЕСТИ'ТЬСЯ** *сов.*— к. вмещаться.

**ВМЕ'СТО** *предлог* — урынына.

**ВМЕТА'ТЬ** I *несов.*— к. вмести.

**ВМЕТА'ТЬ** II *сов.*— типчеп кую, күкләп кую.

**ВМЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — себереп кертелү.

**ВМЁТЫВАТЬ** *несов.*— к. вметать II.

**ВМЁТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — типчеп куелу, күкләп куелу.

**ВМЕША'ТЕЛЬСТВО** *ср.* — 1. тыгылу, катышу; *вмешательство в личные дела* — шәхси эшләргә тыгылу; 2. катнашу; *требуется вмешательство прокуратуры*— прокуратураның катнашуы таләп ителә.

**ВМЕША'ТЬ** *сов.*— 1. катыштыру, аралаштыру, катнаштыру; кушу; 2. *разг. (впутать)* тыгу, бутау, катнаштыру.

**ВМЕША'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тыгылу, кысылу; *вмешаться в чужой разговор* — кеше сүзенә тыгылу; 2. катнашу; *в дело вмешался суд* — эшкә суд катнашты.

**ВМЕ'ШИВАТЬ** I *несов.*— к. вмешать.

**ВМЕ'ШИВАТЬ** II *несов.*— к. вмесить.

**ВМЕ'ШИВАТЬСЯ** I *несов.*— к. вмешаться.

**ВМЕ'ШИВАТЬСЯ** II *несов. страд.*— катнаштырып изелү.

**ВМЕЩА'ТЬ** *несов.* — 1. сыйдыру; 2. урнаштыру, салу.

**ВМЕЩА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. сыю; сыеп бетү; 2. *страд.* урнаштырылу, салыну.

**ВМИГ** *нареч.* — бик тиз, күз ачып-йомганчы.

**ВМИНА'ТЬ** *несов. разг.*— дыңгычлап тутыру, баса-баса тутыру.

**ВМИНА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — дыңгычлап тутырылу, баса-баса тутырылу.

**ВМЯ'ТИНА** *ж.*— яньчелгән урын, сытылган урын.

**ВНАЁМ, ВНАЙМЫ'** *нареч.* — хак түләп вакытлыча файдалануга (алу), хак алып вакытлыча файдалануга (бирү).

**ВНАКИ'ДКУ** *нареч. разг.* — җилкәгә салып, иңбашка салып (киемне).

**ВНАКЛА'ДКУ** *нареч.*— 1. шикәр салып (чәйгә, кофега); 2. *тех.* берсе өстенә берсен куеп.

**ВНАЧА'ЛЕ** *нареч.*— башта, элек.

**ВНЕ** *предлог* — 1. тышта, читтә; *стоять вне общества* — җәмгыятьтән читтә яшәү; 2. ...-сыз; *вне очереди* — чиратсыз; 3. ...-дан тыш; *вне плана* — планнан тыш. ◇ **Вне всяких сомнений** *разг.*— әлбәттә, һичшиксез. **Вне себя от радости**—шатлыгыннан нишләргә белми, шатлыгы эченә сыймый. **Вне себя кричать** — чиксез борчылып кычкыру, үз-үзен белми кычкыру.

**ВНЕВРЕ'МЕННЫЙ** — вакыт белән чикләнмәгән.

**ВНЕДРИ'ТЬ** *сов.* — ныклап урнаштыру, тамыр җәйдерү, кертү.

**ВНЕДРИ'ТЬСЯ** *сов.* — ныклап урнашу, тамыр җәю, керү.

**ВНЕДРЯ'ТЬ** *несов.*— к. внедрить.

**ВНЕДРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. внедриться; 2. *страд.* урнаштырылу, кертелү.

**ВНЕЗА'ПНО** *нареч.* — кинәт, кинәттән, көтмәгәндә.

**ВНЕЗА'ПНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* көтелмәгәнлек, кинәтлек; 2. көтелмәгән вакыйга.

**ВНЕЗА'ПНЫЙ** — көтелмәгән, көтелмәгәндә килеп чыккан, кинәт килеп чыккан.

**ВНЕКЛА'ССНЫЙ** — классийн тыш.

**ВНЕКЛА'ССОВЫЙ** —сыйныфлардан тыш, сыйныфларга бәйләнмәгән.

**ВНЕОЧЕРЕДНО'Й** — чираттан тыш, нәүбәттән тыш.

**ВНЕПЛА'НОВЫЙ** — планнан тыш, планга кермәгән.

**ВНЕСЛУЖЕ'БНЫЙ** — хезмәттән тыш, хезмәттән буш; *во внеслужебное время* — хезмәттән буш вакытта.

**ВНЕСМЕ'ТНЫЙ** — сметадан тыш, сметада каралмаган, сметага кертелмәгән.

**ВНЕСТИ'** *сов.*— к. вносить.

**ВНЕШКО'ЛЬНИК** *м.*, **ВНЕШКО'ЛЬНИЦА** *ж.*— мәктәптән тыш тәрбия эшләре алып баручы.

**ВНЕШКО'ЛЬНЫЙ** — мәктәптән тыш.

**ВНЕ'ШНЕ** *нареч.*— тыштан карауга, тыштан караганда, тышкы яктан (караганда).

**ВНЕШНЕПОЛИТИ'ЧЕСКИЙ** — тышкы политик, тышкы политикага караган.

**ВНЕШНЕТОРГО'ВЫЙ** — тышкы сәүдә ...-ы; *внешнеторговые отношения* — тышкы сәүдә мөнәсәбәтләре.

**ВНЕ'ШНИЙ** — тышкы; *внешний вид* — тышкы күренеш; *внешняя политика* —тышкы политика.

**ВНЕ'ШНОСТЬ** *ж. мн.* нет— тышкы күренеш, кыяфәт.

**ВНЕШТА'ТНЫЙ** — штаттан тыш.

**ВНИЗ** *нареч.*— түбәнгә, аска, түбәнгә таба.

**ВНИЗУ'** — 1. *нареч.* аста, түбәндә; 2. *предлог* астында.

**ВНИКА'ТЬ** *несов.*— аңлау, төшенү, төшенеп эш итү.

**ВНИ'КНУТЬ** *сов.*— к. вникать.

**ВНИМА'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *психол.* дикъкать; 2. *(интерес)* кызыксыну, күңел бирү; 3. *(благосклонное отношение)* игътибар. ◇ **Принимать во внимание** — исәпкә алу, игътибарга алу. **Обратить внимание** — колак салу, күз салу, дикъкать итү.

**ВНИМА'ТЕЛЬНО** *нареч.* — дикъкать белән, игътибар белән.

**ВНИМА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. дикъкатьлелек, игътибарлылык; 2. *(любезность)* ягымлылык, ачык йөзлелек, ачык чырайлылык.

**ВНИМА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *(сосредоточенный)* дикъкатьле; 2. *(любезный, чуткий)* ягымлы, ачык йөзле, ачык чырайлы.

**ВНИМА'ТЬ** *несов. устар.* — дикъкать итү, игътибарга алу, колак салу.

**ВНИЧЬЮ'** *нареч. спорт.* — ничьяга, бер якның да отмавы белән.

**ВНОВЬ** *нареч.* — 1. *(снова)* яңадан, яңа баштан, өр-яңадан, тагын бер кат; 2. *(только что)* күптән түгел, яңа гына.

**ВНОСИ'ТЬ** *несов.* — 1. *(внутрь)* кертү, күтәреп кертү; 2. *(плату)* түләү, акча кертү; 3. кертү, тәкъдим итү; *вносить законопроект* — закон проекты кертү; 4. кертү, теркәү; *вносить в список* — исемлеккә кертү.

**ВНОСИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. кертелү, күтәреп кертелү; 2. түләнү, акча кертелү; 3. тәкъдим ителү, кертелү.

**ВНУК** *м.* — 1. улының яки кызының улы, оныкъ; 2. *только мн. перен.* киләчәк буыннар.

**ВНУ'ТРЕННЕ** *нареч.* — эчтән; күңеленнән, эченнән.

**ВНУТРЕННЕПОЛИТИ'ЧЕСКИЙ** — эчке политик, эчке политикага караган.

**ВНУ'ТРЕННИЙ** — эчке, эчтәге.

**ВНУ'ТРЕННО** *нареч.* — к. внутренне.

**ВНУ'ТРЕННОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* эч; *внутренность дома* — өй эче; 2. урта; *внутренность острова* — утрауның уртасы; 3. *только мн. мед.* эчке органнар.

**ВНУТРИ'** — 1. *нареч.* эчтә; 2. *предлог* эчендә; *внутри дома* — өй эчендә.

**ВНУТРИПАРТИ'ЙНЫЙ** — партия эчендәге, партиянең эчке ... -ы.

**ВНУТРИСОЮ'ЗНЫЙ** — союз эчендәге, союзның эчке ... -ы.

**ВНУТРЬ** — 1. *нареч.* эчкә; 2. *предлог* эченә.

**ВНУЧА'ТА** *только мн.* — оныклар, улларының яки кызларының балалары.

**ВНУ'ЧКА** *ж.* — оныкъ, улының яки кызының кызы.

**ВНУША'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәэсиргә бирелүчәнлек, тәэсиргә бирелү.

**ВНУША'ТЬ** *несов.* — 1. тудыру, уяту, кузгату; *внушать отвращение* — нәфрәт тудыру; 2. *(поучать, наставлять)* әйтә килү, күңеленә салу, төшендерү, киңәш бирү.

**ВНУШЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* тәэсир итү, күңеленә салу, үз ихтыярына буйсындыру; 2. *(совет, наставление)* үгет, үгет бирү; 3. *(выговор)* шелтә, шелтәләү.

**ВНУШИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. тәэсирле, тәэсир итәрлек, күңелдә эз калдырырлык; 2. *разг.* бик зур, бик олы.

**ВНУШИ'ТЬ** *сов.* — к. внушать.

**ВНЯ'ТНО** *нареч.* — ачык итеп, аңлаешлы итеп, ачык ишеттереп.

**ВНЯ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ачыклык, аңлаешлылык.

**ВНЯ'ТНЫЙ** — ачык, аңлаешлы, ачык ишетелә торган.

**ВНЯТЬ** *сов.* — к. внимать.

**ВО I** *предлог* — к. в I, в II. ◇ **Во исполнение** — үтәү йөзеннән. **Во имя победы** — җиңү хакына.

**ВО II** *простореч.* — 1. *указат. частица* менә; 2. *межд.* менә нинди!

**ВО'БЛА** *ж. мн.* нет — вобла (балык).

**ВОБРА'ТЬ** *сов.* — к. вбирать.

**ВОБРА'ТЬСЯ** *сов.* — к. вбираться.

**ВОВЕ'К, ВОВЕ'КИ** *нареч.* — мәңге, беркайчан да.

**ВОВЛЕКА'ТЬ** *несов.* — 1. тарту, катнаштыру, җәлеп итү; *вовлекать в общественную работу* — җәмәгать эшенә тарту; 2. *(соблазнять)* кызыктыру, кызыктырып кертү, кызыктырып тарту, кызыктырып күндерү.

**ВОВЛЕКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. катнашу, катнаша башлау; *вовлекаться в общественную работу* — җәмәгать эшләренә катнашу; 2. *страд.* тартылу, җәлеп ителү.

**ВОВЛЕ'ЧЬ** *сов.* — к. вовлекать.

**ВОВНЕ'** *нареч. книж.* — 1. *(за пределами чего-н.)* тышында, читендә; 2. *(за пределы чего-н.)* тышына, тышка.

**ВОВНУ'ТРЬ** *предлог с род. п. разг.* — к. внутрь.

**ВО'-ВРЕМЯ** *нареч.* — вакытында, вакытлы, нәкъ вакытында.

**ВО'ВСЕ** *нареч. разг.* — бөтенләй, һич тә, бер дә.

**ВОВСЮ'** *нареч. разг.* — бик нык, бөтен көчкә, бөтен көче белән.

**ВО-ВТОРЫ'Х** *ввод. сл.* — икенчедән, икенчеләй.

**ВОГНА'ТЬ** *сов.* — к. вгонять. ◇ **Вогнать в пот** — тиргә батыру. **Вогнать в гроб** — кабергә кертү, гүргә кертү.

**ВО'ГНУТОСТЬ** *ж. мн.* нет — батынкылык, эчкә таба бөгелгәнлек.

**ВО'ГНУТЫЙ** — 1. эчкә бөгелгән; 2. батынкы, эчкә баткан; *вогнутое зеркало* — батынкы көзге.

**ВОГНУ'ТЬ** *сов.* — 1. *(вогнуть внутрь)* эчкә бөгү, эчкә таба бөгү; 2. *(сделать в чём-л. углубление)* батынкылау, батынкы итү.

**ВОГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — эчкә бөгелү, эчкә таба бөгелү.

**ВОДА'** ж. — су; *проточная вода* — агым су; *весенние воды* — язгы сулар; *минеральные воды* — минераль сулар; *лечебные воды* — шифалы сулар. ◇ **Воду в ступе толочь** *разг.* — иләк белән су ташу, комнан бау ишү (файдасыз эш, нәтиҗәсез эш). **Как в воду опущенный** — балтасы суга төшкән кебек (боек, күңелсез кеше турын-

да әйтелә). **Концы в воду** *разг.* — эзен яшерү, очын яшерү. **Их водой не разольёшь** *разг.* — араларыннан җил дә үтми, араларына кыл да сыймый. **Как в воду кануть** *разг.* — суга төшеп югалган кебек булу, җиргә сеңгәндәй булу. **С него как с гуся вода** *разг.* — исе дә китми, колагына да әлми. **Как две капли воды (похожи)** — ике тамчы су кебек (охшаганнар), бер-берсенә бик нык охшаганнар. **Он воды не замутит** *разг.* — тыныч, юаш, басынкы, тыйнак. **Чувствовать себя как рыба в воде** — үзеңне иркен тоту, үзеңне судагы балык кебек хис итү. **Сквозь огонь и воду прошёл** — утны, суны кичкән; дөньяның әчесен-төчесен татыган; төрлесен күргән, күпне күргән. **Из воды сухим выйти** — судан коры чыгу (гаепләнерлек эштән котылу). **На чистую воду вывести** — гаебен ачу, кимчелеген фаш итү. **Быть тише воды, ниже травы** — тыйнак булу, буйсынучан булу. **Много воды утекло** — күп вакытлар үтте, күп сулар акты. **Набрал воды в рот** — авызына су капкан (эндәшми). **Дуть на воду** — авызы пешкән өреп капкан. **С лица не воду пить** — төсне табакка куймыйлар, матурлык туйда гына кирәк (эш матурлыкта түгел). **Седьмая вода на киселе** — күпер башында кучәр башлары эләккән; капка баганалары бертуган; чыбык очы (бик ерак кардәшләр турында әйтелә). **Лить воду на мельницу ...** — ... тегермәненә су кою.

**ВОДВОРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. утырту, урнаштыру; *водворение преступника в тюрьму* — җинаятьчене төрмәгә утырту; 2. *перен.* урнаштыру; *водворение порядка* — тәртип урнаштыру.

**ВОДВОРИ'ТЕЛЬ** *м.* — урнаштыручы; *водворитель новых порядков* — яңа тәртипләр урнаштыручы.

**ВОДВОРИ'ТЬ** *сов* — к. водворять.

**ВОДВОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. водворяться.

**ВОДВОРЯ'ТЬ** *несов.* — 1. *(помещать, поселять)* утырту, урнаштыру; 2. *перен.* урнаштыру; *водворять порядок* — тәртип урнаштыру.

**ВОДВОРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. урнашу; утыру; *водворяться в новом доме* — яңа йортка урнашу; 2. урнашу; *водворяется постепенно порядок* — акрынлап тәртип урнаша; 3. *страд.* урнаштырылу.

**ВОДЕВИЛИ'СТ** *м.* — водевильче, водевиль язучы.

**ВОДЕВИ'ЛЬ** *м. театр.* — водевиль (сәхнә өчен язылган кечкенә генә көлкеле әсәр).

**ВОДЕВИ'ЛЬНЫЙ** — водевиль...-ы; *водевильный куплет* — водевиль куплеты.

**ВОДИ'ТЕЛЬ** *м.* — 1. *книж. устар.* *(вождь)* юлбашчы; *(руководитель)* җитәкче; 2. машина йөртүче (мәсәлән, шофёр, тракторист); *водитель трамвая* — трамвай йөртүче.

**ВОДИ'ТЕЛЬСКИЙ** — йөртүчеләр ...-ы; *водительский состав* — ... йөртүчеләр составы (мәсәлән, шофёрлар составы, трамвай йөртүчеләр составы).

**ВОДИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — җитәкчелек; *под водительством партии* — партия җитәкчелегендә.

**ВОДИ'ТЬ** *несов.* — 1. йөртү, җитәкләп йөртү; *водить больного к доктору* — авыруны докторга йөртү; *водить слепого* — сукыр кешене җитәкләп йөртү; 2. йөртү; *водить трамвай* — трамвай йөртү; 3. алып бару; *водить полки в бой* — полкларны сугышка алып бару; 4. тоту, булу; *водить дружбу, водить хлеб-соль* — дуслык тоту; *водить знакомство* — таныш булу. ◇ **Водить за нос** — алдап йөртү. **Водить хороводы** *устар.* — әйлән-бәйлән уйнау. **Водить глазами** — як-якка карану. **Водить носом** — иснәнү. **Водить детей гулять** — балаларны йөрергә алып чыгу.

**ВОДИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. булу; яшәү; очрау; *в реке водятся щуки* — елгада чуртаннар бар. 2. аралашу, йөрешү; *он водится с рыбаками* — ул балыкчылар белән аралаша. ◇ **Водиться с ребёнком** — бала карау. **Деньги водятся** — акча бар. **Как водится** *разг.* — гадәттәгечә, гадәт буенча, һәрвакыттагыча, йола буенча. **За ним водится этот грех** — аның мондый гаебе бар (булгалый).

**ВО'ДКА** *ж.* — аракы. ◇ **Крепкая водка** *хим.* — азот кислотасы.

**ВО'ДНИК** *м* — водник, су транспортында эшләүче; *профсоюз водников* — су транспорты эшчеләре профсоюзы.

**ВО'ДНЫЙ** — 1. су ...-ы; *водный транспорт* — су транспорты; *водный спорт* — су спорты; 2. сулы; *водные соединения* — сулы кушылмалар.

**ВОДОБО'ЯЗНЬ** *ж. мн.* нет, *мед.* — судан курку (котыру авыруы).

**ВОДОВМЕСТИ'ЛИЩЕ** *ср.* — сулык, су резервуары.

**ВОДОВО'З** *м.* — су ташучы, сучы.

**ВОДОВО'ЗКА** *ж. разг* — 1. су ташый торган ат; 2. *перен.* корчаңгы тай (начар ат, арык ат).

**ВОДОВО'ЗНЫЙ** — су ташу ...-ы, су ташый торган; *водовозная бочка* — су ташый торган мичкә.

**ВОДОВОРО'Т** *м.* — 1. упкын, чоңгыл (елгада һәм диңгездә су бөтерелеп тора торган урын); 2. *перен.* давыл, өермә; *водоворот жизни* — тормыш давылы; *водоворот событий* — вакыйгалар өермәсе.

**ВОДОГРЕ'ЙКА** *ж. тех.* — су җылыткыч, су кайнату приборы.

**ВОДОГРЕ'ЙНЫЙ** *тех.* — су кайната торган, су кайнату ...-ы; *водогрейный котёл* — су кайнату казаны, су кайната торган казан.

**ВОДОЁМ** *м.* — сулык, бассейн (су җыелып тора торган урын).

**ВОДОЁМКИЙ** — 1. *(вмещающий много воды)* су күп сыйдыра торган; *(впитывающий влагу)* дым саклаучан, су сеңдерүчән, юешлек саклаучан.

**ВОДОИЗМЕРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — су үлчәү ...-ы, су үлчәгеч; *водоизмерительные приборы* — су үлчәү приборлары.

**ВОДОИЗМЕЩЕ'НИЕ** *ср. мор.* — водоизмещение; судноның авырлыгы; *водоизме-*

*щение судна 20 000 тонн* — судноның авырлыгы 20 000 тонна.

**ВОДОКА'ЧКА** *ж.* — водокачка.

**ВОДОКРА'С** *м. бот.* — субуяр (үлән), субизәр.

**ВОДОЛА'З** *м.* — 1. водолаз (махсус кием киеп су төбенә төшеп эшләүче кеше); 2. *(порода собак)* водолаз, үрдәк эте.

**ВОДОЛА'ЗНЫЙ** — водолаз ...-ы; су асты ...-ы; су төбендәге; *водолазный костюм* — водолаз киеме; *водолазные работы* — су төбендәге эшләр, су асты эшләре.

**ВОДОЛЕ'Й** *м. спец.* — 1. су түгүче (эшче); 2. *перен. разг.* сүз боткасы, күп сөйләүче (күп сөйләп, аз мәгънә бирүче оратор).

**ВОДОЛЕЧЕ'БНИЦА** *ж. мед.* — су белән дәвалау учреждениесе.

**ВОДОЛЕЧЕ'БНЫЙ** *мед.* — су белән дәвалый торган, су белән дәвалау ...-ы; *водолечебные процедуры* — су белән дәвалау процедуралары.

**ВОДОЛЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.* — су белән дәвалану, су белән дәвалау.

**ВОДОЛИ'В** *м.* — водолив.

**ВОДОМЕ'Р** I *м. тех.* — су үлчәгеч.

**ВОДОМЕ'Р** II *м. зоол.* — су кандаласы.

**ВОДОМЕ'РНЫЙ** — су үлчи торган; *водомерная труба* — су үлчи торган труба.

**ВОДОМО'ИНА** *ж. обл.* — ерганак.

**ВОДОНЕПРОНИЦА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — су үткәрмәү.

**ВОДОНЕПРОНИЦА'ЕМЫЙ** — су үткәрми торган, су үтми торган.

**ВОДОНО'С** *м. обл.* — су ташучы.

**ВОДОНО'СНЫЙ** *геол.* — сулы, дымлы; *водоносный слой земли* — җирнең сулы катлавы.

**ВОДООТВО'ДНЫЙ** *спец.* — су бүлә торган, су тарата торган, су бүлгеч; *водоотводный канал* — су бүлгеч канал.

**ВОДООТЛИ'В** *м. спец.* — су бушату, суын түгү, су чыгару.

**ВОДООТЛИ'ВНЫЙ** — су бушата торган, суын түгә торган, су агыза торган, артык суны чыгарып җибәрә торган; *водоотливное отверстие* — артык суны агыза торган тишек.

**ВОДООЧИСТИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — су чистарткыч.

**ВОДООЧИСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — су чистарта торган, су чистарткыч; *водоочистительные приборы* — су чистарткыч приборлар.

**ВОДОПА'Д** *м.* — шарлавык, шарлама.

**ВОДОПЛА'ВАЮЩИЙ** *зоол.* — су ...-ы; *водоплавающие птицы* — су кошлары.

**ВОДОПОДА'ЧА** *ж.* — су бирү.

**ВОДОПОДЪЁМНИК** *м.* — су күтәрткеч.

**ВОДОПОДЪЁМНЫЙ** *тех.* — су күтәрткеч ...; *водоподъёмная машина* — су күтәрткеч машина.

**ВОДОПО'Й** *м.* — (терлекләргә) су эчертү урыны, су эчерү урыны, туплавык (су буенда терлекләрне туплау урыны).

**ВОДОПО'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет, *обл.* — ташу, язгы ташу, ташкын.

**ВОДОПРОВО'Д** *м.* — водопровод (су белән тәэмин итү өчен ясалган трубалар системасы).

**ВОДОПРОВО'ДНЫЙ** — водопровод ...-ы; *водопроводная станция* — водопровод станциясе.

**ВОДОПРОВО'ДЧИК** *м.* — водопроводчы, водопровод эшчесе.

**ВОДОПРОНИЦА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет — су үткәрүчәнлек.

**ВОДОПРОНИЦА'ЕМЫЙ** — су үткәрә торган, су үткәрүчән.

**ВОДОРАЗДЕ'Л** *м. геогр.* — субүләр (елгаларны һәм елгаларга караган уйсулыкларны бер-берсеннән аера торган калкулык).

**ВОДОРАЗДЕ'ЛЬНЫЙ** — субүләр ...; суны аера торган; *водораздельная линия* — субүләр сызык; *водораздельный хребёт* — суны аера торган сырт.

**ВОДОРО'Д** *м. мн.* нет, *хим.* — водород (иң җиңел, төссез газ).

**ВО'ДОРОСЛЬ** *ж. бот.* — суүсем, бака ефәге.

**ВОДОСБО'Р** *м. бот.* — суҗыяр (казаякчалар семьялыгыннан үлән үсемлек).

**ВОДОСКА'Т** *м.* — шарлавык (елга төбенең кинәт төшеп киткән урынында суның шарлап төшүе).

**ВОДОСЛИ'В** *м. тех.* — су агызгыч (буадагы тиешле биеклектән арткан суны агызу өчен хезмәт итә торган җайланма).

**ВОДОСНАБЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — су белән тәэмин итү.

**ВОДОСТО'ЧНЫЙ** — су агып төшә торган; *водосточная труба* — су агып төшә торган труба.

**ВОДОТОЛЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *разг.* — иләк белән су ташу, комнан бау ишү, юкны бушка әйләндерү (файдасыз эш).

**ВОДОУПО'РНЫЙ** — 1. *тех.* суга чыдам, суга чыдый торган, суга чыдамлы; *водоупорный клей* — суга чыдамлы җилем; 2. *геол.* су үткәрми торган; *водоупорные слои земли* — җирнең су үткәрми торган катлаулары.

**ВОДОХРАНИ'ЛИЩЕ** *ср.* — водохранилище, су саклагыч, су саклау урыны.

**ВО'ДОЧНЫЙ** — аракы ...-ы; *водочный завод* — аракы заводы.

**ВОДРУЖА'ТЬ** *несов.* — к. водрузить.

**ВОДРУЖА'ТЬСЯ** *несов.* — к. водрузиться.

**ВОДРУЗИ'ТЬ** *сов.* — кадап кую, беркетү, өстенә беркетеп кую; *водрузить знамя победы* — җиңү байрагын кадап кую.

**ВОДРУЗИ'ТЬСЯ** *сов. страд.* — кадап куелу, өстенә кадап куелу, кадап беркетеп куелу.

**ВОДЯНЕ'ТЬ** *несов.* — сусыллану.

**ВОДЯНИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет — сусыллык, сулылык.

**ВОДЯНИ'СТЫЙ** — 1. сусыл; *водянистые ягоды* — сусыл җиләкләр; 2. *перен.* эчтәлексез, сыек; *водянистый доклад* — эчтәлексез доклад. ◇ **Водянистые чернила** — сыек кара.

**ВОДЯ'НКА** *ж. мн.* нет, *мед.* — водянка (организмдагы төрле куышлыкларга сары су җыелу).

**ВОДЯНО'Й** I — 1. су ...-ы; *водяной пар* — су пары; *водяная мельница* — су тегермәне; *водяные растения* — су үсемлекләре; 2. су белән ...; *водяное отопление* — су белән жылыту; *водяное охлаждение* — су белән суыту. ◇ **Водяная лилия** *бот.* — ак төнбоек.

**ВОДЯНО'Й** II *миф.* — су анасы, су пәрие.

**ВОДЯ'НОЧНЫЙ** — сары су жыйналудан...; *водяночный отёк* — сары су.

**ВОДЯ'ЩИЙ** — 1. йөртүче; алып баручы; 2. җитәкләп йөртүче; 3. *(в игре)* утаман.

**ВОЕВА'ТЬ** *несов.* — 1. *(вести войну)* сугышу, сугыш алып бару; 2. *перен.* ызгышу, җәнҗаллашу, талашу.

**ВОЕВО'ДА** *м. истор.* — 1. воевода (борынгы Россиядә гаскәр начальнигы); 2. шәһәр башлыгы (XVI — XVIII йөзләрдә); 3. воеводство башлыгы (элек Польшада).

**ВОЕВО'ДСТВО** *ср.* — 1. воеводство, воеводалык (Польшада административ-территориаль берәмлек); 2. *истор.* воевода званиесе, воевода вазифасы.

**ВОЕДИ'НО** *нареч.* — *(в одно целое)* бер итеп; *(вместе)* бергә, бер булып, бергәләшеп.

**ВОЕНАЧА'ЛЬНИК** *м.* — хәрби начальник, гаскәр башлыгы.

**ВОЕНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — хәрбиләштерү; сугыш эшенә өйрәтү; сугыш вакыты шартларына җайлаштыру.

**ВОЕНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. хәрбиләшү, сугыш эшенә өйрәнү; сугыш вакыты шартларына җайлашу; 2. *страд.* хәрбиләштерелү; сугыш эшенә өйрәтелү; сугыш вакыты шартларына җайлаштырылу.

**ВОЕННО-ВОЗДУ'ШНЫЙ** — хәрби-һава ...-ы; *военно-воздушный флот* — хәрби-һава флоты.

**ВОЕННО-ИНЖЕНЕ'РНЫЙ** — хәрби-инженерлык ...-ы; *военно-инженерное дело* — хәрби-инженерлык эше.

**ВОЕННО-МОРСКО'Й** — хәрби-диңгез ... -ы; *военно-морской флот* — хәрби-диңгез флоты.

**ВОЕННООБЯ'ЗАННЫЙ** *м. сущ.* — хәрби учётта торучы (армиядә хезмәт итәргә тиешле кеше).

**ВОЕННОПЛЕ'ННЫЙ** — хәрби пленный, әсир.

**ВОЕННОСЛУ'ЖАЩИЙ** *м. сущ.* — хәрби хезмәткәр.

**ВОЕННО-ТЕХНИ'ЧЕСКИЙ** — хәрби - техник ...; *военно-техническое училище* — хәрби-техник училище.

**ВОЕННО-УЧЕ'БНЫЙ** — хәрби уку ...-ы; *военно-учебное заведение* — хәрби уку йорты.

**ВОЕННОУЧЁТНЫЙ** — хәрби учёт ...-ы; *военноучётный стол* — хәрби учёт өстәле.

**ВОЕ'ННЫЙ** — 1. сугыш ...-ы; *военное время* — сугыш вакыты; 2. хәрби; *военная промышленность* — хәрби промышленность; 3. гаскәри, хәрби; *военная служба* — гаскәри хезмәт. ◇ **Военный коммунизм** *истор.* — хәрби коммунизм.

**ВОЕНРУ'К** *м.* — военрук, хәрби җитәкче.

**ВОЕ'НЩИНА** *ж. мн.* нет — 1. *собир. устар.* гаскәриләр; 2. военщина, сугыш чукмарлары (агрессив империалистик даирәләр).

**ВОЖА'К** *м.* — 1. *(поводырь)* җитәкләп йөртүче; 2. *(проводник)* юл күрсәтүче, юл күрсәтеп баручы; 3. *(в стаде)* көтү башлыгы, *(в табуне)* өер айгыры; 4. *(руководитель)* җитәкче, вожак.

**ВОЖА'ТЫЙ** *м.* — 1. *(проводник)* юл күрсәтүче; 2. *(у пионеров)* вожатый; 3. *(вагоновожатый)* трамвай йөртүче.

**ВОЖДЕЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *устар.* — 1. *(чувственное влечение)* женси теләк; 2. *(сильное желание)* көчле теләк; 3. *(стремление)* омтылыш.

**ВОЖДЕЛЕ'ТЬ** *несов.* — 1. бик нык теләү, омтылу; *вожделеть к богатству* — байлыкка омтылу; 2. *устар.* дәрт килү.

**ВОЖДЬ** *м.* — юлбашчы.

**ВОЖЖА'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — матавыклану, матавыкланып йөрү; маташу, әвәрә булу.

**ВО'ЖЖИ** *ж. мн.* (*ед.* вожжа) — дилбегә. ◇ **Отпустить вожжи** *перен.* — дилбегәне бушатып җибәрү, дилбегәне ычкындыру (дисциплинаны йомшарту мәгънәсендә).

**ВОЗ** *м.* — 1. йөк; йөкле олау, йөкле арба, йөкле чана; 2. *перен. разг.* *(множество)* бик күп; *у него целый воз новостей* — аңарда яңа хәбәрләр бик күп. ◇ **Что с возу упало, то пропало** — йөктән төшкән — югалган.

**ВОЗБЛАГОДАРИ'ТЬ** *сов.* — (тантаналы рәвештә) ризалык белдерү, рәхмәт әйтү; риза булу; шөкер итү; *возблагодарить судьбу* — язмышка шөкер итү, язмыштан риза булу.

**ВОЗБРАНИ'ТЬ** *сов.* — тыю (рөхсәт итмәү).

**ВОЗБРАНЯ'ТЬ** *несов.* — к. возбранить.

**ВОЗБРАНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — тыелу (рөхсәт ителмәү).

**ВОЗБУДИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. тәэсиргә бирелүчәнлек, тәэсиргә бирелү; 2. *биол.* ярсучанлык, уянучанлык.

**ВОЗБУДИ'ТЕЛЬ** *м.* — тудыручы, китереп чыгаручы; *возбудитель болезни* — авыру тудыручы.

**ВОЗБУДИ'ТЬ** *сов.* — к. возбуждать.

**ВОЗБУДИ'ТЬСЯ** *несов.* — к. возбуждаться.

**ВОЗБУЖДА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. возбудимость.

**ВОЗБУЖДА'ТЬ** *несов.* — 1. тудыру, уяту, кузгату, китерү; *возбуждать надежды* — өмет тудыру; *возбуждать аппетит* — ашыйсы китерү; *возбуждать интерес* — кызыксыну тудыру; 2. кузгату; *возбуждать вопрос* — мәсьәлә кузгату; *возбуждать дело в нарсуде* — халык судында эш кузгату; 3. котырту, каршы кую, әчу кабарту; нәфрәтләндерү; *возбуждать всех против себя* — бөтен кешене үзеңә каршы кую; 4. *(приводить в раздражённое состояние)* ярсыту, кыздыру; 5. *физиол.* ярсыту, теләк булдыру, теләк китерү.

**ВОЗБУЖДА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. ярсу, кызу, әсәрләнү; 2. *страд.* тудырылу, уятылу; кузгатылу.

**ВОЗБУЖДЁННО** *нареч.* — ярсып, ярсулы рәвештә, дулкынланып; дәртләнеп, дәрт белән.

**ВОЗБУЖДЁННЫЙ** — 1. кузгатылган; *возбуждённый мною вопрос* — минем тарафтан кузгатылган мәсьәлә; 2. (*взволнованный*) ярсыган, әсәрләнгән, тәэсирләнгән; 3. дәртле, күтәренке рухлы; *возбуждённая речь* — дәртле речь.

**ВОЗВЕЛИ'ЧИВАТЬ** *несов. устар.* — к. возвеличить.

**ВОЗВЕЛИ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. устар.* — 1. к. возвеличиться; 2. *страд.* нык мактау, олылану, хөрмәтләнү.

**ВОЗВЕЛИ'ЧИТЬ** *сов. устар.* — олылау, хөрмәтләү, бик нык мактау, артык мактау, күкләргә күтәрү.

**ВОЗВЕЛИ'ЧИТЬСЯ** *сов. устар.* — мактану, кукраю, масаю, тәкәбберләнү, кәпрәю.

**ВОЗВЕСЕЛИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — бик нык шатландыру, бик нык куандыру (сөендерү).

**ВОЗВЕСЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар.* — бик нык куану, бик нык сөенү; бик нык шатлану.

**ВОЗВЕСЕЛЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. возвеселить.

**ВОЗВЕСЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.* — к. возвеселиться.

**ВОЗВЕСТИ'** *сов. книж.* — к. возводить.

**ВОЗВЕСТИ'ТЬ** *сов. книж. ритор.* — тантаналы рәвештә белдерү, тантаналы рәвештә хәбәр итү, шатлык белән игълан итү.

**ВОЗВЕЩА'ТЬ** *несов. книж. ритор.* — к. возвестить.

**ВОЗВЕЩА'ТЬСЯ** *несов. книж. ритор.* — тантаналы рәвештә белдерелү, тантаналы рәвештә хәбәр ителү; шатлык белән игълан ителү.

**ВОЗВОДИ'ТЬ** *несов.* — 1. торгызу, салу, төзү, кору; *возводить дом* — йорт салу; 2. *мат.* күтәрү; *возводить в степень* — дәрәҗәгә күтәрү. ◇ **Возводить клевету** — яла ягу. **Возводить обвинение** — гаеп ташлау. **Возникновение валунов возводят к ледниковому периоду** — валуннар бозлык чорында барлыкка килгән дип саныйлар. **Возводить на престол** *устар.* — тәхеткә утырту, тәхеткә мендерү. **Возводить в принцип** — принцип итеп кую.

**ВОЗВОДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. торгызылу, салыну, корылу; 2. *мат.* күтәрелү.

**ВОЗВРАТИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*отдать обратно*) кире кайтару, кайтарып бирү; 2. борып кайтару; *возвратить с полдороги* — ярты юлдан борып кайтару.

**ВОЗВРАТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кайту; *возвратиться на родину* — туган илгә кайту; 2. (*вернуться обратно*) кире кайту; борылып кайту; кайтып килү. ◇ **Постепенно возвратились силы после болезни** — авырудан соң әкренләп хәл керде.

**ВОЗВРА'ТНЫЙ** — 1. кайту ...-ы; *возвратный путь* — кайту юлы; 2. *мед.* кайтма, кабатлана торган; *возвратный тиф* — кайтма тиф, кабатлана торган тиф; 3. *лингв.* кайтымлы, кайтым ...-ы; *возвратный глагол* — кайтымлы фигыль; *возвратный залог* — кайтым юнәлеше; 4. кайтаргыч; *возвратная пружина* — кайтаргыч пружина.

**ВОЗВРАЩА'ТЬ** *несов.* — к. возвратить.

**ВОЗВРАЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. возвратиться; 2. *страд.* кайтарылу; *книги возвращаются читателями в библиотеку во-время* — китаплар укучылар тарафыннан көтепханәгә үз вакытында кайтарылалар.

**ВОЗВЫ'СИТЬ** *сов.* — 1. *устар.* күтәрү, дәрәҗәсен күтәрү; *возвысить своего друга в общественном мнении* — җәмәгать фикере алдында иптәшеннең дәрәҗәсен күтәрү; 2. (*о ценах на товары*) арттыру, күтәрү; 3. көчәйтү, күтәрү; *возвысить голос* — тавышны күтәрү.

**ВОЗВЫ'СИТЬСЯ** *сов.* — 1. күтәрелү, дәрәҗәсе күтәрелү; *возвыситься в общественном мнении* — җәмәгать фикере алдында дәрәҗә күтәрелү; 2. (*о ценах на товары*) арту, күтәрелү; 3. *устар.* күтәрелү, арту; *уровень воды возвысился* — су күтәрелде, су артты.

**ВОЗВЫША'ТЬ** *несов.* — 1. к. возвысить; 2. (*создавать приподнятое настроение*) рухландыру, дәртләндерү, рух күтәрү.

**ВОЗВЫША'ТЬСЯ** *несов.* — калкып тору, күтәрелеп тору, биек булып тору; *вдали возвышались горы* — еракта таулар калкып торалар иде.

**ВОЗВЫШЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* (*действие*) күтәрелү; дәрәҗәсе күтәрелү; *история возвышения Рима* — Римның күтәрелү тарихы; 2. (*высокое место*) күтәренке урын, биек урын, калкулык.

**ВОЗВЫ'ШЕННОСТЬ** *ж.* — 1. *геогр.* калкулык, калку җир; 2. *перен. только ед.* (*о чувствах*) күтәренкелек, кәефлелек.

**ВОЗВЫ'ШЕННЫЙ** — 1. (*о местности*) калку; *возвышенное место* — калку җир; 2. *перен.* бөек, югары, күтәренке; *возвышенные цели* — бөек максатлар, югары теләкләр.

**ВОЗГЛА'ВИТЬ** *сов.* — к. возглавлять.

**ВОЗГЛАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — җитәкчелек итү, башында тору, башында бару, идарә итү.

**ВОЗГЛАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җитәкчелек ителү, идарә ителү.

**ВО'ЗГЛАС** *м.* — тавыш; *возглас радости* — шатлык тавышы.

**ВОЗГЛАСИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — тантаналы рәвештә игълан итү, кычкырып белдерү, кычкырып әйтү.

**ВОЗГЛАША'ТЬ** *несов.* — к. возгласить.

**ВОЗГЛАША'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тантаналы рәвештә игълан ителү, кычкырып белдерелү.

**ВОЗГНА'ТЬ** *сов. физ.* — к. возгонять.

**ВОЗГОНЯ'ТЬ** *несов. физ.* — парга әйләндерү, парга әверелдерү.

**ВОЗГОНЯ'ТЬСЯ** *несов. физ.* — парга әйләнү, парга әверелү.

**ВОЗГОРА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. возгореться.

**ВОЗГОРДИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*стать гордым*) масаю, масаеп китү, тәкәбберләнеп

китү; 2. (*начать гордиться*) масая башлау, тәкәбберләнә башлау, борын күтәрә башлау, эреләнә башлау.

**ВОЗГОРЕ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. (*загореться*) янып китү, яна башлау, кабыну, кабынып китү; 2. *перен.* дәрт (теләк) уяну; *возгореться желанием* — теләк уяну, дәрт кабыну; 3. *перен.* башланып китү, кабынып китү; *возгорелся спор* — бәхәс башланып китте.

**ВОЗГРЕМЕ'ТЬ** *сов. устар.* — яңгырап китү, шау итеп китү.

**ВОЗДАВА'ТЬ** *несов.* — к. воздать.

**ВОЗДАВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. воздаться.

**ВОЗДА'ТЬ** *сов.* — 1. (*дать, оказать*) бирү, күрсәтү; *воздать по заслугам* — тиешлесен бирү; 2. (*отплатить*) кайтару, ... итү; *воздать злом за добро* — яхшылыкка яманлык итү. ◇ **Воздать сторицею** — меңләтә кайтару.

**ВОЗДВИГА'ТЬ** *несов.* — торгызу, кору, салу, төзү. ◇ **Воздвигать гонение** *устар.* — эзәрлекләү, эзәрлекли башлау.

**ВОЗДВИГА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — торгызылу, салыну, корылу, төзелү; *в Москве воздвигаются высотные здания* — Москвада биек йортлар салына.

**ВОЗДВИ'ГНУТЬ** *сов. устар. книж.* — к. воздвигать.

**ВОЗДВИ'ГНУТЬСЯ** *сов.* — к. воздвигаться.

**ВОЗДЕВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. воздеть.

**ВОЗДЕВА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — күтәрелү, югары күтәрелү (куллар турында гына әйтелә).

**ВОЗДЕ'ЙСТВИЕ** *ср.* — тәэсир, йогынты.

**ВОЗДЕ'ЙСТВОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — тәэсир итү, йогынты ясау.

**ВОЗДЕ'ЛАТЬ** *сов. устар.* — к. возделывать.

**ВОЗДЕ'ЛЫВАТЬ** *несов.* — 1. эшкәртү; *возделывать землю* — җир эшкәртү; 2. игү; *возделывать пшеницу* — бодай игү.

**ВОЗДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. (*о земле*) эшкәртелү; 2. (*о с.-х. культурах*) игелү.

**ВОЗДЕРЖА'ВШИЙСЯ** *м.* — тавыш бирмәүче, тавыш бирми калучы (тавышка куйганда), кушылмаучы.

**ВОЗДЕРЖА'НИЕ** *ср. мн.* нет — тыелу, үзен тыю, нәфесен тыю; саклану.

**ВОЗДЕ'РЖАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — тыйнаклык, тотнаклылык, сабырлык.

**ВОЗДЕ'РЖАННЫЙ** — тыйнак, сабыр, тотнаклы.

**ВОЗДЕРЖА'ТЬСЯ** *сов.* — 1 (*удержать себя*) тыелып калу, үзенне тыю, үзен-үзе тотып калу; 2. (*не принять участия в голосовании*) катнашмау, тавыш бирмәү, битараф булып калу; 3. (*не принять предложения*) кабул итмәү, кире кагу.

**ВОЗДЕ'РЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. тыелу, тыелып тору; 2. к. воздержаться 2, 3.

**ВОЗДЕ'РЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *устар.* — к. воздержанность.

**ВОЗДЕ'РЖНЫЙ** *устар.* — к. воздержанный.

**ВОЗДЕ'ТЬ** *сов.*: воздеть **руки** — кулларны югары күтәрү.

**ВОЗДОХНУ'ТЬ** *сов. устар.* — к. вздохнуть.

**ВО'ЗДУХ** *м. мн.* нет — һава. ◇ **На вольном воздухе** — саф һавада, тышта. **На открытом воздухе** — ачык һавада, тышта. **Поднять на воздух** — һавага күтәрү (шартлату). **Питаться воздухом** *шутл. разг.* — акча килер җире булмау, ачлы-туклы яшәү.

**ВОЗДУХОПЛА'ВАНИЕ** *ср. мн.* нет — һавада очу (һавадан җиңел булган аппаратка утырып очу).

**ВОЗДУХОПЛА'ВАТЕЛЬ** *м.*, **ВОЗДУХОПЛА'ВАТЕЛЬНИЦА** *ж.* — һавада очучы.

**ВОЗДУХОПЛА'ВАТЕЛЬНЫЙ** — һавада оча торган, һавада очу...-ы; *воздухоплавательный аппарат* — һавада очу аппараты.

**ВОЗДУШНО-ДЕСА'НТНЫЙ** *воен.* — һава десанты ...-ы; *воздушно-десантные войска* — һава десанты гаскәрләре.

**ВОЗДУ'ШНОСТЬ** *ж. мн.* нет — бик җиңеллек.

**ВОЗДУ'ШНЫЙ** — 1. һава ...-ы; *воздушное сообщение* — һава юлы; 2. һавадан, һава ...-ы; *воздушный налёт* — һавадан һөҗүм, һава һөҗүме; 3. һава белән ... ; *воздушное охлаждение* — һава белән суыту; 4. һавада ... ; *воздушная стрельба* — һавада атышу; 5. һаваны ... ; *воздушное наблюдение* — һаваны күзәтү; 6. *перен.* бик җиңел; *воздушное платье* — (һавадай) җиңел күлмәк. ◇ **Воздушные за́мки** — эшкә ашмаслык хыяллар, эшкә ашмаслык планнар. **Воздушная походка** — җиңел йөреш.

**ВОЗДЫМА'ТЬ** *несов. устар.* — к. вздымать.

**ВОЗДЫМА'ТЬСЯ** *несов.* — к. вздыматься.

**ВОЗДЫХА'НИЕ** *ср. устар.* — 1. к. воздыхать; 2. (*сетование*) сукрану, зарлану.

**ВОЗДЫХА'ТЬ** *несов. устар.* — к. вздыхать.

**ВОЗЗВА'НИЕ** *ср.* — өндәмә, воззвание.

**ВОЗЗВА'ТЬ** *сов. поэт.* — к. взывать.

**ВОЗЗРЕ'НИЕ** *ср.* — караш, фикер.

**ВОЗЗРЕ'ТЬ** *сов.* — к. взирать.

**ВОЗЗРИ'ТЬСЯ** *сов. просторец.* — текәләп карау, төбәп карау.

**ВОЗИ'ТЬ** *несов.* — ташу, йөртү. ◇ **Возить воду** *на ком-л.* — эт жиктерү (авыр эш кушып интектерү).

**ВОЗИ'ТЬСЯ** I *несов. разг.* — 1. азаплану, маташу; *возиться с багажом* — багаж белән азаплану; 2. (*суетиться*) кайнашу, ыгы-зыгы килү, мәш килү.

**ВОЗИ'ТЬСЯ** II *несов. страд.* — ташылу, йөртелү.

**ВО'ЗКА** *ж. разг.* — 1. *только ед.* к. возить; 2. ... юллык, ... тапкыр барырлык; *дров осталось возок на пять* — биш юллык утын калды.

**ВОЗЛАГА'ТЬ** *несов.* — 1. кую, өстенә (салып яки яткырып) кую; 2. *перен.* йөк-

ләү, тапшыру; *возлагать ответственность* — җаваплылык йөкләү; *возлагать поручение* — йомыш тапшыру. ◇ **Возлагать надежды** — өмет тоту, өмет баглау. **Возлагать вину** — гаепләү, гаеп ташлау.

**ВОЗЛАГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. куелу, өстенә куелу; 2. йөкләнү, тапшырылу, өстенә йөкләнү.

**ВО'ЗЛЕ** I *нареч.* — якында гына; *он живёт возле* — ул якында гына тора.

**ВО'ЗЛЕ** II *предлог с род. п.* — янында; *возле дома* — өй янында.

**ВОЗЛЕЖА'ТЬ** *несов. устар.* — яту (берәр нәрсә өстендә).

**ВОЗЛЕ'ЧЬ** *сов. устар.* — менеп яту.

**ВОЗЛИКОВА'ТЬ** *сов. устар.* — бик нык шатлану, артык дәрәҗәдә сөенү, артык куану, түбәсе күккә (түшәмгә) тию.

**ВОЗЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — к. возлагать.

**ВОЗЛЮБИ'ТЬ** *сов. устар.* — сөю, ярату.

**ВОЗЛЮ'БЛЕННАЯ** *ж. в знач. сущ.* — 1. *(любимая)* сөйгән яр; 2. *(любовница)* сөяркә.

**ВОЗЛЮ'БЛЕННЫЙ** *устар.* — 1. сөекле, сөйгән, яраткан; *возлюбленное дитя* — сөекле бала; 2. *в знач. сущ.* сөйгән кеше(се), яраткан кеше(се).

**ВОЗМЕ'ЗДИЕ** *ср.* — җәза; *заслуженное возмездие* — тиешле җәза.

**ВОЗМЕСТИ'ТЕЛЬ** *м.* — түләүче; *возместитель расходов* — расходларны түләүче.

**ВОЗМЕСТИ'ТЬ** *сов.* — 1. түләү, каплау, кайтару; *возместить расходы* — расходларны түләү; *возместить потерянное время усиленной работой* — югалган вакытны тырышып эшләү белән каплау (кайтару); 2. *(заменить недостающее)* тутыру.

**ВОЗМЕЧТА'ТЬ** *сов.* — 1. *устар.* хыялга чуму, хыяллану; 2. *(возмечтать о себе)* үзен зурга куя башлау, тәкәбберләнеп китү, тәкәбберләнә башлау.

**ВОЗМЕЩА'ТЬ** *несов.* — к. возместить.

**ВОЗМЕЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. түләнү, каплану, кайтарылу; 2. *(недостающее чем-н.)* тутырылу.

**ВОЗМНИ'ТЬ** *сов. устар.* — к. возомнить.

**ВОЗМО'ЖНО** I — 1. *нареч.* мөмкин кадәр; *возможно скорее* — мөмкин кадәр тизрәк; 2. *в знач. сказ. безл.* — мөмкин, булуы мөмкин; *очень возможно* — бик мөмкин; *я сделаю всё, что возможно* — мөмкин булганның барысын да эшләрмен.

**ВОЗМО'ЖНО** II *ввод. сл.* — ихтимал, бәлки, бәлкем; *мне, возможно, придётся уехать* — миңа, бәлки, китәргә туры килер.

**ВОЗМО'ЖНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед. (вероятность)* ихтималлык; 2. *только ед.* мөмкинлек; *мне представляется возможность поехать на юг* — миңа көньякка китәргә мөмкинлек бар; 3. *только мн.* мөмкинлекләр; *производственные возможности* — производство мөмкинлекләре. ◇ **По возможности** (или **по мере возможности**) — мөмкин кадәр, хәл кадәренчә, мөмкин булганча, хәлдән килгәнчә. **До последней возможности** — актык чиккә кадәр. **При первой возможности** — мөмкин булгач та.

**ВОЗМО'ЖНЫЙ** — мөмкин булган; ихтимал булган; булуы мөмкин булган; *дело, возможное только в далёком будущем* — бик ерак киләчәктә генә булуы мөмкин булган эш.

**ВОЗМО'ЧЬ** *сов. устар.* — хәлдән килү.

**ВОЗМУЖА'ВШИЙ** — к. возмужалый.

**ВОЗМУЖА'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — олыгайганлык, балигъ булганлык.

**ВОЗМУЖА'ЛЫЙ** — буйга җиткән, үсеп җиткән, олыгайган, балигъ булган, олы кеше чырае кергән.

**ВОЗМУЖА'ТЬ** *сов.* — үсеп җитү, буйга җитү, балигъ булу.

**ВОЗМУТИ'ТЕЛЬ** *м. устар.* — фетнәче, коткы салучы; бозучы, тынгысызлаучы; *возмутитель спокойствия* — тынычлыкны бозучы.

**ВОЗМУТИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — ачу килерлек, ачу китерерлек.

**ВОЗМУТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. ачу китерерлек, ачу китергеч, ачу кабарткыч; 2 *устар.* коткы сала торган; *возмутительные речи* — коткы сала торган сүзләр.

**ВОЗМУТИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(привести в негодование)* ачуын китерү, ачуландыру; 2. болгату; *возмутить воду* — суны болгату; 3. бозу; *возмутить спокойствие* — тынычлыкны бозу; 4. *устар. (побудить к мятежу)* котырту, коткы салу, чуалту, болгату.

**ВОЗМУТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(прийти в негодование)* ачу килү, ачу кабару, кәеф кырылу; 2. *устар. (восстать против кого-л.)* баш күтәрү, чуалышу.

**ВОЗМУЩА'ТЬ** *несов.* — к. возмутить.

**ВОЗМУЩА'ТЬСЯ** *несов.* — к. возмутиться.

**ВОЗМУЩЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* ачу. *прийти в возмущение* — ачу килү; 2. *устар; (мятеж)* чуалыш, баш күтәрү, фетнә; 3. *астр.* тайпылыш, тайпылу (күк җисеменең башка планеталар тартуы тәэсирендә үзенең орбитасыннан тайпылуы).

**ВОЗМУЩЁННО** *нареч.* — ачуланып, кызып.

**ВОЗМУЩЁННЫЙ** — 1. ачуы килгән, ачуы кабарган; 2. ачулы; *возмущённый голос* — ачулы тавыш.

**ВОЗНАГРАДИ'ТЬ** *сов.* — бүләкләү; хакын бирү, тиешлесен бирү.

**ВОЗНАГРАЖДА'ТЬ** *несов.* — к. вознаградить.

**ВОЗНАГРАЖДА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — бүләкләнү; хакы бирелү, тиешлесе бирелү.

**ВОЗНАГРАЖДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. (действие)* к. вознаградить; 2. бүләк; түләү; *денежное вознаграждение* — акчалата түләү; акчалата бүләк.

**ВОЗНАМЕ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — к. вознамериться.

**ВОЗНАМЕ'РИТЬСЯ** *сов. книж.* — уйлау, чамалау, теләү, ният итү, ниятләү; *войска вознамерились занять город* — гаскәрләр шәһәрне алырга ниятләделәр.

**ВОЗНЕГОДОВА'ТЬ** *сов. книж.* — ачулану, бик нык кәеф кырылу, ачу кабару.

**ВОЗНЕНАВИ'ДЕТЬ** *сов.* — дошман күрү, яратмау, күрәсе килмәү.

**ВОЗНЕСТИ'** *сов. книж. устар.* — күтәрү, күкләргә күтәрү.

**ВОЗНЕСТИ'СЬ** *сов.* — 1. *устар. поэт. (подняться вверх)* югарыга күтәрелү, күкләргә күтәрелү; 2. *неодобр. (возгордиться)* тәкәбберләнеп китү, масаеп китү.

**ВОЗНИКА'ТЬ** *несов.* — барлыкка килү, килеп чыгу, туу.

**ВОЗНИ'КНУТЬ** *сов.* — к. возникать.

**ВОЗНИ'ЦА** *м. устар.* — ямщик, кучер.

**ВОЗНИ'ЧИЙ** *м. устар.* — к. возница.

**ВОЗНОСИ'ТЬ** *несов. устар.* — к. вознести.

**ВОЗНОСИ'ТЬСЯ** *несов. устар.* — к. вознестись.

**ВОЗНЯ'** *ж. мн.* нет — 1. шау-шу, тавыш, ыгы-зыгы; *дети подняли возню* — балалар шау-шу күтәрделәр; 2. *(хлопоты)* мәшәкать.

**ВОЗОБЛАДА'ТЬ** *сов. книж.* — өстенлек алу, өстен чыгу; җиңеп чыгу.

**ВОЗОБНОВИ'ТЬ** *сов.* — яңадан башлау, яңарту, яңадан башлап җибәрү; *возобновить переговоры* — сөйләшүләрне яңадан башлап җибәрү.

**ВОЗОБНОВИ'ТЬСЯ** *сов.* — яңадан башлану, яңадан башланып китү; *занятия возобновились* — занятиеләр яңадан башланып киттеләр.

**ВОЗОБНОВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. возобновить.

**ВОЗОБНОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — возобновиться.

**ВОЗО'К** *м. устар.* — көймәле чана.

**ВОЗОМНИ'ТЬ** *сов. устар.*: **возомнить о себе** — масаеп китү, үзен әллә кемгә саный башлау, үзен әллә кемгә кую.

**ВОЗОПИ'ТЬ** *сов. устар.* — акыра башлау, бакыра башлау, кычкыра башлау.

**ВОЗРА'ДОВАТЬСЯ** *сов. устар.* — шатлану, куану, сөенү.

**ВОЗРАЖА'ТЬ** *несов.* — каршы килү, каршы әйтү, каршы төшү.

**ВОЗРАЖЕ'НИЕ** *ср.* — 1. к. возражать; 2. *(несогласие)* каршылык; *веское возражение* — урынлы каршылык.

**ВОЗРАЗИ'ТЬ** *сов.* — к. возражать.

**ВО'ЗРАСТ** *м.* — яшь; *дети школьного возраста* — мәктәп яшендәге балалар; *я одного возраста с ним* — мин аның белән бер яшьтә. ◇ **Войти в возраст** — буйга җиту, үсеп җиту. **Выйти из возраста** — яшьтән чыгу (билгеле яшьтән үтеп китү). **Преклонный возраст** — картлык. **На возрасте** — буйга җиткән.

**ВОЗРАСТА'ТЬ** *несов.* — *(расти)* үсү; *(увеличиваться)* арту; *(усиливаться)* көчәю.

**ВОЗРАСТИ'** сов. — к. возрастать.

**ВОЗРАСТИ'ТЬ** *сов. устар.* — к. взрастить.

**ВОЗРАСТНО'Й, ВО'ЗРАСТНЫЙ** — яшь ...-ы; *возрастные особенности* — яшь үзенчәлекләре. ◇ **Возрастные группы населения** — халыкның яшь ягыннан группаларга бүленеше.

**ВОЗРАЩА'ТЬ** *несов. устар.* — к. возрастить.

**ВОЗРЕВНОВА'ТЬ** *сов. книж. устар.* — тырышлык күрсәтү, омтылыш күрсәтү.

**ВОЗРОДИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(восстановить)* яңадан торгызу, аякка бастыру; 2. *(внушить энергию)* уяту; җанландыру, рухландыру, дәрт кертеп җибәрү.

**ВОЗРОДИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(восстановиться)* аякка басу; 2. яңадан туу; *во мне возродилось желание учиться* — миндә уку теләге яңадан туды; 3. *(почувствовать прилив сил)* рух күтәрелеп китү, җанланып китү.

**ВОЗРОЖДА'ТЬ** *несов.* — к. возродить.

**ВОЗРОЖДА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. возродиться; 2. *страд.* торгызылу, аякка бастырылу.

**ВОЗРОЖДЕ'НИЕ** I *ср. мн.* нет — 1. *(восстановление)* торгызу, яңадан торгызу, аякка бастыру; торгызылу, яңадан торгызылу, аякка бастырылу; 2. *(подъём сил)* дәртләнү, җанлану, яңа көч керү.

**ВОЗРОЖДЕ'НИЕ** II *ср. мн.* нет — Возрождение, Яңарыш, Ренессанс; *эпоха Возрождения* — Возрождение эпохасы, Яңарыш эпохасы (XV — XVI йөзләрдә Европада капиталистик мөнәсәбәтләр туу уңае белән культура һәм идеология алга киткән чор).

**ВОЗРОПТА'ТЬ** *сов. поэт.* — ризасызлык белдерү.

**ВО'ЗЧИК** *м.* — олаучы, йөк ташучы, йөк йөртүче, йөкче.

**ВОЗЫМЕ'ТЬ** *сов.* — тою, хис итү, сизү; *возыметь намерение* — теләк барлыгын тою. ◇ **Возыметь действие** — тәэсир итү, тәэсирсез калмау; *его слова возымели своё действие* — аның сүзләре тәэсирсез калмады.

**ВО ИЗБЕЖА'НИЕ** — ... булмасын өчен,... килеп чыкмасын өчен ..., котылу өчен, ... булдырмас өчен; *во избежание неприятностей* — күңелсезлекләр килеп чыкмасын өчен.

**ВО'ИН** *м.* — сугышчы, солдат.

**ВО'ИНСКИЙ** — 1. хәрби, гаскәри; *воинская повинность* — хәрби хезмәт; 2. гаскәриләрчә, хәрбиләрчә, гаскәри; *воинский вид* — гаскәри кыяфәт; *его поведение совсем не воинское* — аның үз-үзен тотышы һич тә хәрбиләрчә түгел.

**ВОИ'НСТВЕННО** *нареч.* — 1. сугышчан рәвештә; 2. *перен.* әтәчләнеп, сугышырга әзер торган хәлдә.

**ВОИ'НСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. сугышчанлык; 2. *перен.* сугышырга (тарткалашырга, бәхәсләшергә, сүз көрәштерергә) әзер торучанлык.

**ВОИ'НСТВЕННЫЙ** — сугышчан, сугыш яратучан.

**ВО'ИНСТВО** *ср. устар. поэт.* — хәрби көчләр; гаскәр, сугышчылар.

**ВО'ИНСТВУЮЩИЙ** — 1. сугышчан, сугышучан; 2. актив көрәшүчән; *воинствующий материализм* — актив көрәшүчән материализм.

**ВОИ'СТИНУ** *нареч. устар.* — чынлап та, дөрестән дә.

**ВОИ'ТЕЛЬ** *м. устар. поэт.* — 1. (*воин*) сугышчы; 2. *разг.* (*драчун*) сугыш чукмары.

**ВОЙ** *м. мн.* нет — 1. улау, улаган тавыш, улау тавышы; *слышен вой волка* — бүре улаган тавыш ишетелә; 2. *перен.* акырыну; *бешеный вой реакционных газет* — реакцион газеталарның котырынып акырынуы; 3. (*немелодическое пение*) улау, акыру; 4. (*громкий протяжный плач*) улау, сузып елау.

**ВО'ЙЛОК** *м.* — 1. *только ед.* киез; 2. (*кусок войлока*) киез кисәге, киез.

**ВО'ЙЛОЧНИК** *м.*, **ВО'ЙЛОЧНИЦА** *ж.* — киез басучы.

**ВО'ЙЛОЧНЫЙ** — 1. киез ...; *войлочная шляпа* — киез эшләпә; 2. киез басу ...-ы, киез ...-ы; *войлочное производство* — киез басу производствосы.

**ВОЙНА'** *ж.* — сугыш; *Великая Отечественная война* — Бөек Ватан сугышы. ◇ **Развязать войну** — сугыш башлау, сугыш башлап җибәрү.

**ВО'ЙСКО** *ср.* (*мн.* войска́) — гаскәр, яу.

**ВОЙСКОВО'Й** — гаскәри; *войсковые части* — гаскәри частьлар.

**ВОИТИ'** *сов.* — к. входить 1, 2, 3, 5.

**ВОКАБУЛА'РИЙ** *м. устар.* — сүзлек (хрестоматиягә яки дәреслекнең аерым өлешләренә кыскача сүзлек).

**ВОКА'БУЛЫ** *ед.* нет, *устар.* — вокабуллар (яттан өйрәнү өчен язып алынган чит тел сүзләре һәм аларның тәрҗемәләре).

**ВОКАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — вокализация (1. *муз.* тавышны яхшырту өчен нота буенча текстсыз җырлау; 2. *лингв.* тартык авазның сузык авазга күчүе).

**ВОКАЛИ'ЗМ** *м. лингв.* — вокализм (телдә сузык авазлар системасы).

**ВОКАЛИ'СТ** *м. муз.* — вокалист (җырлаучының яки җырчының тавышын тәртипкә салучы белгеч).

**ВОКА'ЛЬНЫЙ** *муз.* — вокаль, җыр ...-ы; *вокальный вечер* — җыр кичәсе.

**ВОКЗА'Л** *м.* — вокзал.

**ВОКЗА'ЛЬНЫЙ** — вокзал ...-ы; *вокзальное здание* — вокзал бинасы.

**ВОКРУ'Г** I *нареч.* — тирә-юньдә, әйләнә-тирәдә. ◇ **(Ходить, бродить) вокруг да около** — мәсьәләнең асылына төшенеп җитмәү, мәсьәләне аңлап җиткермәү.

**ВОКРУ'Г** II *предлог с род. п.* — тирәсендә, әйләнәсендә; *вокруг дома* — өй тирәсендә.

**ВОЛ** *м.* — печкән үгез, эш үгезе. ◇ **Вола вертеть (или крутить)** *простореч.* — юкны бушка әйләндерү, вакытны бушка үткәрү, вакытны мәгънәсезгә үткәрү.

**ВОЛГА'РЬ** *м. обл.* — 1. (*уроженец Поволжья*) Волга буенда туып үскән кеше; 2. (*судовой рабочий в Поволжье*) Волга пароходларындагы эшче.

**ВО'ЛГЛЫЙ** *обл.* — дымлы, дым тарткан, дымланган.

**ВО'ЛГНУТЬ** *несов. обл.* — дымлану, дым тарту.

**ВОЛДЫ'РЬ** *м. разг.* — куык, кабарчык, сулы бетчә.

**ВОЛЕВО'Й** — нык ихтыярлы; *волевой командир* — нык ихтыярлы командир.

**ВОЛЕИЗЪЯВЛЕ'НИЕ** *ср. книж. офиц.* — 1. ризалык белдерү, теләк белдерү; 2 (*приказание*) боеру, кушу.

**ВОЛЕЙБО'Л** *м. спорт.* — волейбол (туп уенының бер төре).

**ВОЛЕЙБОЛИ'СТ** *м.*, **ВОЛЕЙБОЛИ'СТКА** *ж.* — волейболчы, волейбол уйнаучы.

**ВОЛЕЙБО'ЛЬНЫЙ** — волейбол ... -ы; *волейбольный мяч* — волейбол тубы.

**ВО'ЛЕЙ-НЕВО'ЛЕЙ** *нареч.* — ирекле-ирексез, ихтыярлы-ихтыярсыз, теләр-теләмәс, ирексездән.

**ВОЛЖА'НИН** *м.*, **ВОЛЖА'НКА** *ж.* — Волга буенда торучы, Волга буенда туган.

**ВО'ЛЖСКИЙ** — Волга ... -ы; *волжское пароходство* — Волга пароходствосы.

**ВОЛК** *м.* — бүре. ◇ **Волком выть** *разг.* — бүре булып улау (әрнеп, ачынып зарлану). **Волк в овечьей шкуре** — сарык тиресенә төренгән бүре (икейөзле кеше). **Волком смотреть** — бүре шикелле карау (ачуланып карау). **С волками жить — по волчьи выть** *погов.* — бүреләр белән яшәсәң, бүре кебек уларсың; кем арбасына утырсаң, шунын җырын җырларсың. **Волков бояться — в лес не ходить** — бүредән курыккан урманга бармас.

**ВОЛКОДА'В** *м.* — бүре эте, бүре куа торган эт, бүре тота торган эт.

**ВОЛНА'** *ж.* — дулкын; *морская волна* — диңгез дулкыны; *звуковая волна* — тавыш дулкыны; *волна рабочего движения* — эшчеләр хәрәкәте дулкыны.

**ВОЛНЕ'НИЕ** *ср.* — 1 (*о поверхности воды*) дулкынлану; 2. (*беспокойство, тревога*) борчылу, тынычсызлану; 3. *перен. чаще мн.* чуалыш; *крестьянское волнение* — крестьяннар чуалышы.

**ВОЛНИ'СТЫЙ** — 1. дулкынлы, дулкынсыман, дулкынланып тора торган; 2. таулы-чокырлы, тигезсез; *волнистая местность* — таулы-чокырлы урын. ◇ **Волнистое железо** — сырлы тимер.

**ВОЛНОВА'ТЬ** *несов.* — 1. (*водную поверхность*) дулкынландыру; 2. (*беспокоить, тревожить*) борчу, күңелнең тынычлыгын бозу; 3. *устар.* (*подстрекать к волнениям*) котырту, тәртипсезлек тудыруга өндәү. ◇ **Волновать умы** — фикер уяту, фикер кузгату.

**ВОЛНОВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. (*о море, ниве*) дулкынлану; 2. *перен.* (*тревожиться*) борчылу, тынычсызлану; 3. *устар.* (*бунтовать*) чуалу, чуалыш ясау, кузгалу. ◇ **Улица волнуется** — урам айкала. **Кровь волнуется** — кан уйный, кан кыза. **Мысли волнуются** — башка төрле фикерләр килә.

**ВОЛНОВО'Й** — 1. *физ.* дулкынлану ...-ы; *волновая теория* — дулкынлану теориясе;

2. дулкынсыман; *волновое движение* — дулкынсыман хәрәкәт; 3. (*производящий волны*) дулкынландыручы; 4. дулкын ... -ы; *волновая скорость* — дулкын тизлеге.

**ВОЛНООБРА'ЗНЫЙ** — 1. дулкынсыман, дулкын-дулкын; 2. (*неровный*) таулы-чокырлы, тигезсез.

**ВОЛНУ'ЮЩИЙ** — 1. дулкынландыра торган, кызыксындыра торган; *вопросы, волнующие массы* — массаларны дулкынландыра торган мәсьәләләр; 2. борчулы, борчый торган, тынычсызлый торган, шомлы; *волнующие события* — шомлы вакыйгалар; 3. сокландыргыч, сокландыра торган; *волнующий голос* — соклангыч тавыш.

**ВОЛО'ВИЙ** — 1. үгез ... -ы; *воловья шкура* — үгез тиресе; 2. *перен.* бик нык; *тут нужно иметь воловьи нервы* — биредә бик нык нервлар кирәк.

**ВОЛОВИ'К** *м. бот.* — үгез теле.

**ВОЛО'ВИНА** *ж. обл.* — 1. (*мясо*) үгез ите; 2. (*шкура*) үгез тиресе.

**ВОЛОВНЯ'** *ж.* — үгез абзары.

**ВО'ЛОК** *м.* — волок (көймәләрне бер елгадан икенчесенә сөйрәп күчерә торган тар урын).

**ВОЛОКИ'ТА** I *ж. мн.* нет — волокита (артык формальлеккә бирелеп эшне озакка сузу, мәшәкать арттыру). ◇ **Бумажная волокита** — кәгазь боткасы.

**ВОЛОКИ'ТА** II *м. разг. устар.* — хатын-кыз артыннан йөрүче.

**ВОЛОКИ'ТНЫЙ** — волокиталы, мәшәкатьле, матавыклы.

**ВОЛОКНИ'СТЫЙ** — 1. сүсчел; 2. җепселле.

**ВОЛОКНО'** *ср.* — 1. сүс; *льняное волокно* — житен сүсе; 2. (*в тканях животных и растений*) җепсел.

**ВО'ЛОКОМ** *нареч.* — сөйрәп, өстерәп.

**ВОЛОКУ'ША** *ж.* — 1. сөйрәткеч, чүмәлә тарткыч; 2. (*род рыболовной сети*) сөрәкә; 3. (*род бороны*) атлы тырма, сөйрәткеч (җир тигезләү өчен кулланалар); 4. *воен.* волокуша (сугыш кырында карлы яки сазлыклы җирләрдә сугыш әйберләрен күчерү өчен кулланыла торган җайланма).

**ВОЛОНТЁР** *м.* — волонтёр (үзе теләп гаскәри хезмәткә баручы).

**ВОЛОНТЁРНЫЙ, ВОЛОНТЁРСКИЙ** — волонтёрлар ... -ы; *волонтёрская форма* — волонтёрлар формасы.

**ВО'ЛОС** *м.* (*мн.* во́лосы) — 1. чәч бөртеге; 2. (*на хвосте лошадей, коров и др.*) кыл; 3. (*на коже человека*) төк; (*на коже животных*) йон; ябага; 4. *зоол.* төк корты, йон корты. ◇ **Краснеть до корней волос** — чәч төпләренә кадәр кызару (бик нык оялу, оялудан кызару). **Дело не подвинулось ни на волос** — эш урыныннан да кузгалмады. **Волосы стали дыбом** — чәчләре үрә торды. **Ни на́ волос** — бөтенләй юк, һич юк.

**ВОЛОСА'ТИК** *м.* — 1. *зоол.* җеп елан, су суалчаны; 2. *бот.* нечкә кузгалак, чыпчык кузгалагы.

**ВОЛОСА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — йонтәслек, йон басканлык.

**ВОЛОСА'ТЫЙ** — 1. (*покрытый волосами*) йонлы; төкле; йонлач; 2. *разг.* (*чрезмерно обросший волосами*) йон баскан; озын чәчле (ир кеше турында әйтелә).

**ВОЛОСИ'НКА** *ж.* — чәч бөртеге.

**ВОЛОСО'К** *м.* — 1. к. волос; 2. (*тонкая пружинка в карманных часах*) кыл, сәгать кылы; 3. *бот.* җепсел. ◇ **На волоске висеть (держаться)** — кыл өстендә тору. **Не тронуть волоска** — бармак та тидермәү, бармак белән дә кагылып карамау.

**ВО'ЛОСТЬ** *ж. устар.* — волость (элекке административ-территориаль берәмлек).

**ВО'ЛОСЫ** *мн.* (*ед.* во́лос) — чәч.

**ВОЛОСЯ'НИК** *м. обл.* — кыл матрац.

**ВОЛОСЯ'НКА** *ж.* — 1. (*ткань из конского волоса*) кыл тукыма; 2. (*силок*) кыл тозак.

**ВОЛОСЯНО'Й** — 1. йон ...-ы; төк ...-ы; *волосяной покров* — йон капламы; 2. кыл ...; кылдан ясалган; *волосяной матрац* — кыл матрац.

**ВОЛОЧИ'ТЬ** *несов.* — 1. өстерәү, сөйрәү; өстерәп (сөйрәп) алып бару (килү); *волочить мешок по земле* — капчыкны җирдән өстерәп алып бару; 2. *тех.* ясау; *волочить проволоку* — металл чыбык ясау; 3. *перен.* (*таскать*) интектереп йөртү. ◇ **Волочить лён** — житен талку. **Еле ноги волочить** *разг.* — көч-хәл белән атлау, көчкә-көчкә генә йөрү.

**ВОЛОЧИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. (*тащиться по земле*) өстерәлү, сөйрәлү; өстерәлеп сөйрәлеп) бару (килү); 2. (*о проволоке*) ясалу; 3. *разг. устар.* (*ухаживать за женщиной*) хатын-кыз артыннан йөрү.

**ВОЛХВ** *м. устар.* — күрәзә, сихерче, багучы.

**ВОЛХВОВА'ТЬ** *несов. устар.* — сихерчелек итү, күрәзәлек итү, багучылык итү.

**ВОЛЧА'НКА** *ж. мн. нет, мед.* — волчанка, тире туберкулёзы (авыру).

**ВОЛЧЕ'Ц** *м.* — 1. *бот.* кузлут; 2. *вет.* яман тимрәү (этләрнең башында һәм муенында була).

**ВО'ЛЧИЙ** — 1. бүре ...-ы; *волчий след* — бүре эзе; 2. бүре тиресеннән тегелгән; *волчья шуба* — бүре тиресеннән тегелгән тун. ◇ **Волчий билет, паспорт** *дореволюц.* — кәҗә билеты (революциягә кадәр дәүләт хезмәтенә яки уку йортына алырга ярамаган кешеләргә бирелә торган белешмә яки паспорт). **Волчья яма** *воен.* — бүре чокыры (төбенә очлы казыклар кагып куелган чокыр). **Волчья ягода** — бүре җиләге, карга миләше. **Волчий аппетит** *перен. разг.* — бик нык ашыйсы килү. **Волчья хватка** — ычкындырмаслык итеп тоту.

**ВОЛЧИ'ХА, ВОЛЧИ'ЦА** *ж.* — ана бүре.

**ВОЛЧКО'М** *нареч.* — бөтергеч кебек; *вертеться волчком* — бөтергеч кебек бөтерелү.

**ВОЛЧО'К** *м.* (игрушка) — бөтергеч, бөтерчек.

**ВОЛЧО'НОК** *м.* (*мн.* волчата) — бүре баласы.

**ВОЛШБА'** *ж. мн.* нет, *устар.* — сихерчелек, күрәзәлек.

**ВОЛШЕ'БНИК** *м.*, **ВОЛШЕ'БНИЦА** *ж.* — сихерче, күрәзә, тылсымчы (әкиятләрдә).

**ВОЛШЕ'БНЫЙ** — 1. (*в сказках — действующий волшебством*) сихерле, тылсымлы; 2. *перен.* искиткеч матур, искитәргеч, сокландыргыч; *волшебный голос* — сокландыргыч тавыш.

**ВОЛШЕБСТВО'** *ср. мн.* нет — 1. (*колдовство*) сихер, сихерчелек; 2. *перен.* (*очарование*) сокландыру, сихерләү; тылсымлы тәэсир.

**ВОЛЫ'НИТЬ** *несов. простореч.* — 1. тоткарлау, эшне юри озакка сузу; 2. ялкаулану, ирену; *не волынь, а работай* — ялкауланма, эшлә.

**ВОЛЫ'НИТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. юри озак эшләү, юри әкрен эшләү; 2. ялкаулану, иренеп кенә эшләү.

**ВОЛЫ'НКА** *ж.* — 1. (*музыкальный инструмент*) сорнай; 2. *только ед. разг.* акрынлык, сүлпәнлек, матавыклык; *прекратить эту волынку* — бу сүлпәнлекне бетерергә кирәк.

**ВОЛЫ'НЩИК** *м.* — 1. (*музыкант*) сорнайчы; 2. *перен. разг. неодобр.* бюрократ; (*медленно работающий*) акрын эшләүче.

**ВОЛЬГО'ТНЫЙ** *разг.* — иркен, рәхәт; *вольготное житьё* — иркен тормыш, рәхәт тормыш.

**ВО'ЛЬНАЯ** *ж. истор.* — азатлык кәгазе, азатлык язуы (крепостнойлыктан азат итү турында бирелгән язу).

**ВО'ЛЬНИЦА** — 1. *ж. собир.* качаклар (борынгы вакытта боярлардан качып китеп, рәсми җәмгыятькә кермичә местәкыйль рәвештә яшәүче кешеләр); 2. *м.* и *ж.* шаян, шук, үзирекле.

**ВОЛ'ЬНИЧАТЬ** *несов.* — башбаштаклык итү, ни теләсә шуны эшләү, үзе теләгәнен эшләү, бернәрсә белән дә исәпләшмәү.

**ВО'ЛЬНО** *нареч.* — иркен; *вольно вести себя* — үзеңне иркен тоту. ◇ **Вольно или невольно** — теләсәң-теләмәсәң.

**ВОЛЬНО'** *в знач. сказ. разг.* — үзе(н) гаепле; үзеңә үпкәлә; кем кушкан сиңа; *ушибся? вольно же тебе было лазить по деревьям* — авырттырдыңмы? агач башларына менеп йөрергә кем кушкан сиңа.

**ВОЛЬНОДУ'МЕЦ** *м. устар.* — хөр фикерле кеше.

**ВОЛЬНОДУ'МИЕ** *ср. мн.* нет, *устар.* — к. вольнодумство.

**ВОЛЬНОДУ'МНИЧАТЬ** *сов.* — к. вольнодумствовать.

**ВОЛЬНОДУ'МНЫЙ** *устар.* — хөр фикерле; *вольнодумные стихи Пушкина* — Пушкинның хөр фикерле шигырьләре.

**ВОЛЬНОДУ'МСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.* — хөр фикерлелек (буржуаз-дворяннар җәмгыятендә дингә яки яшәп килә торган тәртипләргә тәнкыйть күзе белән карау).

**ВОЛЬНОДУ'МСТВОВАТЬ** *несов. устар.* — хөр фикерлелек күрсәтү.

**ВОЛЬНОЛЮБИ'ВЫЙ** *устар.* — азатлык сөюче, ирек(лек) сөюче.

**ВОЛЬНОМЫ'СЛИЕ** *ср. мн.* нет — к. вольнодумство.

**ВОЛЬНОНАЁМНЫЙ** — 1. вольнонаёмный, ирекле рәвештә яллангән, үзе теләп яллангән (хәрби хезмәттә булмыйча хәрби ведомствода эшләүче); 2. (*нештатный*) штаттан тыш.

**ВОЛЬНООТПУ'ЩЕННИК** *м.*, **ВОЛЬНООТПУ'ЩЕННИЦА** *ж. истор.* — ирекка җибәрелгән кол, азат ителгән кол (яки крепостной).

**ВОЛЬНОПРАКТИКУ'ЮЩИЙ** — хосусый, частный (хезмәткә кермичә, үз белгечлеге буенча шәхси эш алып баручы).

**ВОЛЬНОСЛУ'ШАТЕЛЬ** *м.*, **ВОЛЬНОСЛУ'ШАТЕЛЬНИЦА** *ж. дореवол.* — ирекле тыңлаучы (революциягә кадәр югары мәктәптә, рәсми студент булмыйча, лекцияләр тыңлап йөрүче).

**ВО'ЛЬНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* (*свобода, независимость*) азатлык, бәйсезлек, ирeклелек; 2. (*излишняя непринуждённость, нескромность*) үзирeклелек, башбаштаклык, тыйнаксызлык.

**ВО'ЛЬНЫЙ** — 1. (*свободный, независимый*) азат, бәйсез, ирекле; 2. (*непринуждённый, нескромный*) башбаштак, үзирекле, тыйнаксыз; 3. (*привольный*) иркен; *вольное житьё* — иркен тормыш. ◇ **Вольный перевод** — ирекле тәрҗемә. **На вольном воздухе** — саф һавада, тышта.

**ВОЛЬТ** *м. физ.* — вольт (электр тогы көчәнешен үлчәү берәмлеге).

**ВОЛЬТИЖИ'РОВАТЬ** *несов. спорт.* — ат өстендә төрле гимнастик хәрәкәтләр ясау.

**ВОЛЬТМЕ'ТР** *м. физ.* — вольтметр (электр чылбырының ике ноктасы арасындагы көчәнешне үлчәү приборы).

**ВОЛЮНТАРИ'ЗМ** *м. мн.* нет — волюнтаризм (1. идеалистик философиядә һәрнәрсәнең нигезе ихтыяр дип раслаучы һәм табигатьтә, җәмгыятьтә объектив закончалыкны инкарь итүче реакцион юнәлеш; 2. идеалистик психологиядә ихтыярны психик тормышның төп факторы итеп караучы юнәлеш).

**ВОЛЮНТАРИ'СТ** *м. филос. псих.* — волюнтарист, волюнтаризм яклы кеше.

**ВОЛЮНТАРИСТИ'ЧЕСКИЙ** *псих. филос.* — волюнтаристик, волюнтаризм ...-ы; *волюнтаристическая теория* — волюнтаризм теориясе.

**ВО'ЛЯ** I *ж. мн.* нет — ирек; *выпустить птицу на волю* — кошны ирекка чыгару; *дать волю своим чувствам* — үз хисләреңә ирек кую. ◇ **На воле** — тышта, саф һавада. **Давать волю языку** — телне тыймау.

**ВО'ЛЯ** II *ж. мн.* нет — 1. ихтыяр: *сильная воля* — көчле ихтыяр; 2. омтылыш, омтылу; *воля к победе* — җиңәргә омтылу; 3. теләк; *воля избирателей* — сайлаучыларның теләге. ◇ **Ваша воля** — ихтыярыгыз, теләсәгез ни эшләгез. **Последняя воля** — васыять.

**ВОМЧА'ТЬ** *сов. разг.* — чаптырып алып керү.

**ВОМЧА'ТЬСЯ** *сов.* — чабып килеп керү.

**ВОН** I — 1. *нареч.* читкә, тышка, читенә, тышына; *каша вылезла вон из горшка* — ботка чүлмәкнең тышына ташып чыкты; 2. *в знач. сказ.* чыкты, юк булды; *из головы вон* — баштан чыкты; 3. *в знач. пов. накл.* кит, чыгып кит, югал, юк бул, ычкын; *вон отсюда!* — кит моннан! ◇ **Из рук вон (плохо)** — үтә начар, кулга алмаслык начар. **Лезть вон из кожи** — шартлардай булып көчәнү. **Дух вон** — үлде, бетте, җаны чыкты. **Из ряда вон выходящий** — дөньяда булмаган.

**ВОН** II *частица* — әнә, менә; *вон он идёт* — әнә ул килә; *вон там* — әнә тегендә; *вон видишь, что случилось* — менә күрәсең, нәрсә килеп чыкты.

**ВО'НА** *нареч. просторечь.* — 1. әнә; *вона он пошёл* — әнә ул китте; 2. шулаймыни! алай икән! *Вона! так, стало быть, он уже уехал!* — Шулаймыни! ул, димәк, китеп тә барган инде!

**ВОНЗА'ТЬ** *несов.* — к. вонзить.

**ВОНЗА'ТЬСЯ** *несов.* — к. вонзиться.

**ВОНЗИ'ТЬ** *сов.* — кадау, чәнчү, кадап кую, чәнчеп кую. ◇ **Вонзить взор** — текәп карау.

**ВОНЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — чәнчелү, кадалу.

**ВОНЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — сасы ис.

**ВОНЮ'ЧИЙ** — сасы, сасы исле.

**ВОНЮ'ЧКА** *ж.* — 1. *зоол.* сасы бурсык; 2. *бот.* сасы үлән; 3. *ж.* и *м. просторечь. фам.* сасык, һава бозучы (кеше).

**ВОНЯ'ТЬ** *несов. разг.* — сасыту, сасы ис чыгару, һава бозу.

**ВООБРАЖА'ТЬ** *несов.* — 1. *(представлять)* күз алдына китерү, хыял итү; 2. *(предполагать, думать)* фараз итү, гөман итү, ... дип уйлау; 3. *(воображать о себе)* үзен әллә кемгә санау, үзен әллә кемгә кую, үзен зурга санау, тәкәбберләнү, кукраю, кәпрәю, мактану.

**ВООБРАЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *(представляться)* күз алдына килү; 2. *(предполагаться)* фараз ителү, гөман ителү, ... дип уйлану.

**ВООБРАЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — хыял, фараз.

**ВООБРАЗИ'ТЬ** *сов.* — к. воображать.

**ВООБРАЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. воображаться.

**ВООБЩЕ'** *нареч.* — 1. гомумән, гомумән алганда; *вообще вы правы* — гомумән сез хаклы; 2. гел, һәрвакыт; *вообще он такой весёлый* — ул гел шулай шат күңелле; 3. гомумән, бөтенләй; *я вообще сегодня никуда не пойду* — мин бүген гомумән (бөтенләй) беркая да бармыйм.

**ВООДУШЕВИ'ТЬ** *сов.* — к. воодушевлять.

**ВООДУШЕВИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. воодушевляться.

**ВООДУШЕВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(действие)* к. воодушевлять; 2. *(состояние)* дәрт, күтәренке рух; илһам; *с воодушевлением взялись за работу* — эшкә дәрт белән (дәртләнеп) керештеләр.

**ВООДУШЕВЛЁННО** *нареч.* — күтәренке рух белән, дәртле рәвештә, дәртләнеп.

**ВООДУШЕВЛЯ'ТЬ** *несов.* — рухландыру, рухын күтәрү, дәртләндерү; җанландыру.

**ВООДУШЕВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. дәртләнү, рухлану, рух күтәрелү, җанлану; 2. *страд.* дәртләндерелү, рухландырылу, җанландырылу.

**ВООРУЖА'ТЬ** *несов.* — 1. коралландыру; 2. тәэмин итү, коралландыру; *мы вооружаем наше с.-х. машинами* — без авыл хуҗалыгын машиналар белән тәэмин итәбез, коралландырабыз; 3. *(восстанавливать против кого-л.)* котырту, дошман итү, дошманлаштыру.

**ВООРУЖА'ТСЯ** *несов.* — 1. коралланy; 2. *страд.* коралландырылу. ◇ **Вооружаться терпением** — чыдау, чыдарга тырышу.

**ВООРУЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(действие)* к. вооружать, вооружаться; 2. *(оружие)* корал.

**ВООРУЖЁННОСТЬ** *ж.* — коралланганлык, коралланган булу, коралланy дәрәҗәсе; *высокая техническая вооружённость советского сельского хозяйства* — совет авыл хуҗалыгының техник яктан югары дәрәҗәдә коралланган булуы.

**ВООРУЖЁННЫЙ** — 1. коралланган; *вооружённый пулемётом* — пулемёт белән коралланган; 2. кораллы; *вооружённое восстание* — кораллы восстание. ◇ **Вооружённым глазом** — оптик прибор аша карап. **Вооружённые силы** — кораллы көчләр (гаскәр, армия). **Вооружённый до зубов** — баштанаяк коралланган.

**ВООРУЖИ'ТЬ** *сов.* — к. вооружать.

**ВООРУЖИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. вооружаться 1.

**ВОО'ЧИЮ** *нареч.* — үз күзе белән, үзе күреп, үзе сынап.

**ВО-ПЕ'РВЫХ** *ввод. сл.* — беренчедән, беренчеләй.

**ВОПИ'ЛА** *м.* и *ж. просторечь.* — бакыручы, акыручы кеше, елак (бала).

**ВОПИ'ТЬ** *несов. разг.* — акыру, бакыру, кычкыру, акырып елау.

**ВОПИЮ'ЩИЙ** — күзгә бәрелеп тора торган, искитәрлек, шаккатарлык; *вопиющий факт* — күзгә бәрелеп тора торган факт. ◇ **Глас вопиющего в пустыне** — җавапсыз (игътибарсыз) калган таләп (чакыру).

**ВОПИЯ'ТЬ** *несов. устар.* — 1. кычкырып ялвару, ялварып сорау, инәлеп сорау; 2. шапырынып кычкыру. ◇ **Камни вопиют** — хурлыгыннан үләрсен.

**ВО'ПЛЕНИЦА** *ж. обл.* — ялланып елаучы (мәет озатканда).

**ВОПЛОТИ'ТЬ** *сов. книж.* — гәүдәләндерү ◇ **Воплотить в жизнь** — тормышка ашыру.

**ВОПЛОТИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — гәүдәләнү. ◇ **Воплотиться в жизнь** — тормышка ашу.

**ВОПЛОЩА'ТЬ** *несов.* — к. воплотить.

**ВОПЛОЩА'ТЬСЯ** *несов.* — к. воплотиться.

**ВОПЛОЩЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *(действие)* к. воплотить, воплотиться; 2. гәүдәләнеш; нәкъ үзе; *Плюшкин — это воплощение скупости* — Плюшкин саранлыкның гәүдәләнеше ул.

**ВОПЛОЩЁННЫЙ** — ашырылган; *проект, воплощённый в жизнь* — тормышка ашырылган проект. ◇ **Этот человек — воплощённая справедливость** — бу кеше — бик гадел кеше.

**ВОПЛЬ** *м.* — акыру, кычкырып елау, үксеп елау; ачы тавыш, кычкырган тавыш.

**ВОПРЕКИ'** *предлог с дат. п.* — ...-га карамастан, ...-га каршы; *вопреки моему желанию* — теләгемә каршы, теләгемә карамастан.

**ВОПРО'С** *м.* — 1. сорау; *задать вопрос* — сорау бирү; 2. мәсьәлә; *спорный вопрос* — бәхәсле мәсьәлә. ◇ **Что за вопрос** *разг.* — әлбәттә, мөмкин. **Под большим вопросом** — ышанычсыз, шикле, икеле. **Риторический вопрос** — риторик сорау (җавап таләп итми торган сорау). **Пришёл по личному вопросу** — үз эше белән килде. **Вопрос жизни и смерти** — бик мөһим мәсьәлә. **Это ещё вопрос** — бу әле икеле (шикле).

**ВОПРОСИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — сорагансыман; *вопросительно посмотреть (на кого-л.)* — сорагансыман карау.

**ВОПРОСИ'ТЕЛЬНЫЙ** — сорау ...-ы, сораулы, сорагансыман; *вопросительный знак* — сорау билгесе; *вопросительная интонация* — сораулы интонация; *вопросительный взгляд* — сораулы караш, сорагансыман карау.

**ВОПРОСИ'ТЬ** *сов. устар.* — к. вопрошать.

**ВОПРО'СНИК** *м.* — сораулык, сораулар исемлеге, сораулар тезмәсе.

**ВОПРО'СНЫЙ** — сораулар ...-ы; *вопросный лист* — сораулар кәгазе, анкета.

**ВОПРОША'ТЬ** *несов. устар., теперь ирон.* — сорау, сорау бирү.

**ВОПРОША'ТЬСЯ** *несов. страд. устар.* — соралу, сорау бирелү.

**ВОР** *м.* — карак. ◇ **На воре шапка горит** — каракның бүреге яна.

**ВОРВА'ТЬСЯ** *сов.* — бәреп керү, басып керү, кинәт килеп керү; ватып керү, җимереп керү; *наши бойцы ворвались в окопы противника* — безнең сугышчылар дошман окопларына бәреп керделәр.

**ВОРИ'ШКА** *м.* — карак кисәге, вак карак.

**ВОРКОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *(о голубях)* гөрләү, гөрләшү; 2. *перен. (любезничать)* серләшү, авызга-авыз куеп сөйләшү.

**ВОРКОТА'ТЬ** *несов. обл.* — 1. к. ворковать; 2. *(мурлыкать)* мырлау, мырылдау.

**ВОРКОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *разг.* — сукрану, мыгырдау; *бабушкина воркотня* — әбинең мыгырдавы.

**ВОРКОТУ'Н** *м.*, **ВОРКОТУ'НЬЯ** *ж. обл.* — к. ворчун.

**ВОРКУ'Н** *м.* — 1. *(голубь)* мисыр күгәрчене, йорт күгәрчене; 2. *перен.* мыгырдык, берәзгә, сукранучан кеше.

**ВОРОБЕ'Й** *м.* — чыпчык. ◇ **Стреляный воробей** или **старый воробей** — күпне күргән, күпне белгән, тәҗрибәле, карт бүре. **Старого воробья на мякине не проведёшь** — карт чыпчыкны кибәк белән алдый алмассың.

**ВОРОБЬЁНОК** *м. (мн.* воробьята) *обл.* — чыпчык баласы.

**ВОРОБЬИ'НЫЙ** — чыпчык ...-ы; *воробьиное гнездо* — чыпчык оясы. ◇ **Воробьиная ночь** — 1. яшенле төн; 2. җәйге кыска төн. **Короче воробьиного носа** — бик кечкенә, инә очы кадәр генә.

**ВОРОБЬИ'ХА** *ж. простореч.* — ана чыпчык.

**ВОРО'ВАННЫЙ** — урланган, урлап алынган.

**ВОРОВА'ТО** *нареч.* — каракларча.

**ВОРОВА'ТЫЙ** *разг.* — караксыман, хәйләкәр.

**ВОРОВА'ТЬ** *несов.* — 1. урлау; 2. *(заниматься воровством)* урлашу, караклык итү.

**ВОРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — урлану.

**ВОРО'ВКА** *ж.* — карак (хатын-кыз).

**ВОРОВСКИ'** *нареч.* — *(как вор)* каракларча; *(украдкой)* хәйләкәр рәвештә, хәйләкәр генә, яшертен, сиздермичә генә; *воровски взглянули друг на друга* — сиздермичә генә бер-берсенә карашып алдылар.

**ВОРОВСКО'Й** — 1. караклар ...-ы; *воровское арго* — караклар аргосы (теле); 2. *устар.* законсыз, җинаятьле.

**ВОРОВСТВО'** *ср. мн.* нет — караклык; урлашу. ◇ **Литературное воровство** — әдәби караклык, плагиат.

**ВО'РОГ** *м. обл., нар.-поэт.* — дошман; *злой ворог* — явыз дошман.

**ВОРОЖБА'** *ж. мн.* нет, *устар.* — күрәзәлек, багучылык.

**ВОРОЖЕЯ'** *ж. устар.* — күрәзәче, багучы, фалчы (хатын).

**ВОРОЖИ'ТЬ** *несов. устар.* — 1. *(колдовать)* сихерләү; 2. *(гадать)* күрәзәлек итү, багучылык итү.

**ВО'РОН** *м.* — козгын (кош). ◇ **Ворон ворону глаз не выклюет** — карга күзен карга чукымый.

**ВОРО'НА** *ж.* — 1. карга, ала карга; 2. *перен. (ротозей)* ачык авыз. ◇ **Ворон считать** *разг.* — авыз ачып тору. **Пуганая ворона куста боится** — үз шәүләсеннән үзе курка; курыкканга куш күренә. **Ворона в павлиньих перьях** *пренебр.* — салам торхан.

**ВОРОНЁНОК** *м. (мн.* воронята) — карга баласы, ала карга баласы.

**ВОРО'НИЙ** — карга ...-ы, ала карга ...-ы; *воронье крыло* — карга канаты. ◇ **Вороний глаз** *бот.* — карга күзе.

**ВОРО'НИТЬ** *несов. простореч.* — авыз ачып тору.

**ВОРОНИ'ТЬ** *несов.* — каралту, кара төскә кертү (металлның өстен).

**ВОРОНИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — каралтылу, кара төскә кертелү (металл турында).

**ВОРО'НКА** *ж.* — 1. *(для переливания)* бүрәнкә, воронка; 2. *(от снаряда)* снаряд чокыры.

**ВОРОНО'Й** — кара; *вороная лошадь* — кара ат. ◇ **Прокатить на вороных** — кара шар салу, тавыш бирмәү.

**ВОРОНЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир.* — 1. козгыннар; үләксә кошлары; 2. *перен.* ерткычлар, козгыннар; *белогвардейское воронье* — акгвардияче ерткычлар.

**ВО'РОТ** I *м.* — яка, изү, яка уентысы.

**ВО'РОТ** II *м. тех.* — чыгыр, кое чыгыры.

**ВОРО'ТА** только *мн.* — капка, капкалар. ◇ **Триумфальные ворота** — триумфаль капка (берәр зур вакыйга уңае белән шәһәргә керү юлына салынган монументаль капка).

**ВОРОТИ'ЛА** *м. разг. неодобр.* — эшкуар; уз кубызына биетүче; *воротилы Уолл-Стрита* — Уолл-Стрит эшкуарлары.

**ВОРОТИ'ТЬ** I. *сов. разг.* — 1. *(возвратить)* кайтару, кире кайтару, борып кайтару; 2. *(отдать обратно)* кайтару, кайтарып бирү, кире бирү; 3. *(получить обратно)* кайтарып алу.

**ВОРОТИ'ТЬ** II. *несов. простореч.* — 1. *(сворачивать)* юл бирү, читкә каеру (юлда очрашканда); 2. *(распоряжаться)* әйләндерү, эш йөртү, зур эшләр белән идарә итү. ◇ **С души воротит** *разг.* — косасыны китерә, күңелне болгата, саруны кайната (нәфрәт тудырганда әйтелә).

**ВОРОТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. вернуться.

**ВОРОТНИ'К** *м.* — яка; *отложной воротник* — кайтарма яка.

**ВОРО'ТНЫЙ** — капка ... -ы; *воротный крюк* — капка келәсе, капка бигe.

**ВО'РОХ** *м.* — 1. *(куча обмолоченного хлеба)* көшел, өем; 2. *перен.* бер өем; *ворох бумаги на столе* — өстәл өстендә бер өем кәгазь; 3. *перен.* бик күп, тулып ята; *ворох новостей* — бик күп яңалыклар, бик күп яңа хәбәрләр.

**ВОРОХНУ'ТЬ** *сов. разг.* — *(о сене)* кабартып алу; *(о топливе в печи)* болгатып алу.

**ВОРОХНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кыймылдау, селкенү; *сидит — не ворохнется* — утыра, селкенми дә.

**ВОРО'ЧАТЬ** *несов. разг.* — 1. әйләндерү, әйләндереп кую, әйләндереп салу; *ворочать больного с боку на бок* — авыруны бер яктан икенче якка әйләндерү; 2. *(шевелить)* кузгату, кыймылдату, селкетү; 3. әйләндерү; *ветер ворочает крылья мельницы* — җил тегермән канатларын әйләндерә; 4. эш йөртү, башкару; *он у нас всем ворочает* — ул безнең бөтен эшебезне башкара; 5. *обл.* юл бирү, читкә каеру, читкә керү, читкә сугылу; *ну, ворочай с дороги* — я, юлдан читкә сугыл.

**ВОРО'ЧАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. әйләнгәләү; *всю ночь ворочался и не мог заснуть* — төн буе әле бер якка, әле икенче якка әйләнгәләп чыктым, йоклый алмадым; 2. кыймылдау; *ворочайтесь живее* — тизрәк кыймылдагыз.

**ВОРОШИ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. *(о сене)* кабарту; 2. *(о топливе в печи)* болгату; 3. *(вообще)* кыймылдату, әйләндерү, астын өскә әйләндерү; тузгыту; *ветер ворошит мои волосы* — җил чәчемне тузгыта.

**ВОРОШИ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. кыймыллау, мыж килү, мыжлап тору; *в навозе ворошились жуки* — тирестә коңгызлар мыж килә иде; 2. *страд.* кабартылу; болгатылу; әйләндерелү, тузгытылу.

**ВОРОШО'К** *м. обл.* — 1. к. ворох; 2. кыяк тавышы, кыштырдаган тавыш.

**ВОРС** *м. мн.* нет — ворс, йон, төк (йон һәм ефәк тукымаларның уң ягындагы төк); *против ворса* — йон уңаена каршы; *по ворсу* — йон уңаена.

**ВОРСИ'НА, ВОРСИ'НКА** *ж.* — төк бөртеге.

**ВОРЧА'ТЬ** *несов.* — 1. *(о собаке)* ырлау, ырылдау; 2. *(о человеке)* мыгырдау, сукрану.

**ВОРЧЛИ'ВО** *нареч.* — мыгырданып, сукранып.

**ВОРЧЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — мыгырдаучанлык, сукранучанлык.

**ВОРЧЛИ'ВЫЙ** — мыгырдаучан, сукранучан, мыгырдавык.

**ВОРЧУ'Н** *м.*, **ВОРЧУ'НЬЯ** *ж. разг.* — мыгырдык кеше, һәрвакыт сукранучы, мыгырдаучы.

**ВОСВОЯ'СИ** *нареч. фам. шутл.*: **отправиться восвояси** — кайтып китү.

**ВОСЕМНА'ДЦАТЫЙ** — унсигезенче.

**ВОСЕМНА'ДЦАТЬ** — унсигез.

**ВО'СЕМЬ** — сигез.

**ВО'СЕМЬДЕСЯТ** — сиксән.

**ВОСЕМЬСО'Т** — сигез йөз.

**ВОСЕМЬЮ'** *нареч.* — сигез тапкыр, сигез җирдә; *восемью восемь — шестьдесят четыре* — сигез җирдә сигез—алтмыш дүрт, сигез сигезең — алтмыш дүрт.

**ВОСК** *м. мн.* нет — балавыз.

**ВОСКЛИ'КНУТЬ** *сов. однокр.* — әйтү, дию; әйтеп кую, кычкырып кую.

**ВОСКЛИЦА'НИЕ** *ср.* — тавыш; *раздались радостные восклицания* — шатлыклы тавышлар яңгырап китте.

**ВОСКЛИЦА'ТЕЛЬНЫЙ** — өндәү ...-ы; *восклицательный знак* — өндәү билгесе.

**ВОСКЛИЦА'ТЬ** *несов. устар.* — кычкыру, кычкырып нидер әйтү.

**ВОСКОБО'ИНА** *ж. с.-х.* — балавыз алгыч (умартачылыкта).

**ВОСКОБО'Й** *м. мн.* нет — балавыз сыгу.

**ВОСКОБО'ЙНЫЙ** — балавыз сыгу ... -ы; балавыз сыга торган; *воскобойная установка* — балавыз сыга торган җайланма.

**ВОСКО'ВКА** *ж. спец.* — восковка, балавызлы кәгазь.

**ВОСКОВО'Й** — 1. балавыз ...; *восковая свечка* — балавыз шәм; 2. *перен.* сары, балавыздай сары; *старуха с восковым лицом* — сары йөзле карчык.

**ВОСКРЕСА'ТЬ** *несов.* — 1. *рел.* яңадан терелү, үлгәннән соң терелү; 2. *перен.*

*(оживать)* җанлану, дәртләнү, рухлану, көч керү.

**ВОСКРЕСЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *рел.* яңадан терелү, үлгәннән соң терелү; 2. *перен. (возрождение)* яңадан туу, рухи яктан уяну, җанлану.

**ВОСКРЕСЕ'НЬЕ** *ср.* — якшәмбе.

**ВОСКРЕСИ'ТЬ** *сов.* — 1. *рел.* терелтү, яңадан терелтү, үлгәннән соң терелтү; 2. *перен. (возобновить)* яңарту, яңадан булдыру, яңадан бар итү; 3. *перен. (возродить)* җанландыру, көч кертү, хәл кертү, җанландырып җибәрү, көч кертеп җибәрү; 4. *перен.* күз алдына китереп бастыру, искә төшерү; *памятники воскресили перед нами жизнь прошлого* — памятниклар үткән заман тормышын безнең күз алдыбызга китереп бастырдылар.

**ВОСКРЕ'СНИК** *м.* — өмә, якшәмбе өмәсе.

**ВОСКРЕ'СНУТЬ** *сов.* — 1. к. воскресать 1; 2. *перен.* җанланып китү, дәртләнеп китү, рухланып китү, көч керү.

**ВОСКРЕ'СНЫЙ** — якшәмбе ... ; *воскресный день* — якшәмбе көн.

**ВОСКРЕША'ТЬ** *несов.* — к. воскресить.

**ВОСКРЫЛИ'ТЬ** *сов. устар.* — канатландыру, рухландыру, рух бирү, дәртләндерү, дәрт бирү, рухландырып җибәрү, дәртләндереп җибәрү.

**ВОСКРЫЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. воскрылить.

**ВОСКРЫЛЯ'ТЬСЯ** *несов. устар.* — рухлану, дәртләнү.

**ВОСКУРИ'ТЬ** *сов.* — к. воскурять.

**ВОСКУРЯ'ТЬ** *несов. устар.*: **воскурять фимиам** *перен.* — мактау, үтә олылау, артык мактау.

**ВОСКУРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. устар.* — макталу, үтә макталу.

**ВОСЛЕ'Д** *нареч. устар.* — к. вслед.

**ВОСПАЛЕ'НИЕ** *ср. мед.* — ялкынсыну; *воспаление лёгких* — үпкәләрнең ялкынсынуы.

**ВОСПАЛЁННЫЙ** — 1. *мед.* ялкынсынган; *воспалённые глаза* — ялкынсынган күзләр; 2. *перен.* әсәрле; *воспалённый взор* — әсәрле карау.

**ВОСПАЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *мед.* — ялкынсыну ...-ы; *воспалительный процесс* — ялкынсыну процессы.

**ВОСПАЛИ'ТЬ** *сов.* — к. воспалять.

**ВОСПАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. воспаляться.

**ВОСПАЛЯ'ТЬ** *несов.* — көчәйтү, кыздыру, кабызу, ярсыту, уяту.

**ВОСПАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *устар.* көчәю, кызу; кабару; *воспаляться гневом* — ачу кабару; 2. *мед.* ялкынсыну.

**ВОСПАРИ'ТЬ** *сов. устар. поэт.* — 1. очып менү; 2. рух күтәрелү, илһам килү, күкләргә очу.

**ВОСПАРЯ'ТЬ** *несов. устар. поэт.* — к. воспарить.

**ВОСПЕВА'ТЕЛЬ** *м. устар. поэт.* — мактап җырлаучы, үтә мактаучы.

**ВОСПЕВА'ТЬ** *несов.* — мактап җырлау, шигырьләрдә мактау.

**ВОСПЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — макталу (җырда, шигырьдә).

**ВОСПЕ'ТЫЙ** — макталган (җырда, шигырьдә).

**ВОСПЕ'ТЬ** *сов.* — к. воспевать.

**ВОСПИТА'НИЕ** *ср. мн. нет* — тәрбия; тәрбияләү; *коммунистическое воспитание* — коммунистик тәрбия; *воспитание молодёжи* — яшьләрне тәрбияләү.

**ВОСПИ'ТАННИК** *м.*, **ВОСПИ'ТАННИЦА** *ж.* — 1. тәрбияләнүче; 2. *(ребёнок, взятый на воспитание)* тәрбиягә алынган бала; 3. *устар. (учащийся)* укучы.

**ВОСПИ'ТАННОСТЬ** *ж. мн. нет* — тәрбиялелек, әдәплелек.

**ВОСПИ'ТАННЫЙ** — 1. тәрбияләнгән; 2. *(благовоспитанный, вежливый)* тәрбияле, әдәпле.

**ВОСПИТА'ТЕЛЬ** *м.*, **ВОСПИТА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — 1. тәрбияче; 2. *(педагог)* укытучы.

**ВОСПИТА'ТЕЛЬНЫЙ** — тәрбияви, тәрбия бирә торган; тәрбия ...-ы; *воспитательное значение* — тәрбияви әһәмият; *воспитательные методы* — тәрбия методлары. ◇ **Воспитательный дом** *дореvол.* — тәрбия йорты.

**ВОСПИТА'ТЕЛЬСКИЙ** — тәрбияче ...-ы; *воспитательская работа* — тәрбияче эше.

**ВОСПИТА'ТЬ** *сов.* — 1. тәрбияләү, тәрбияләп үстерү; *воспитать ребёнка* — баланы тәрбияләү; 2. тудыру, булдыру; *воспитать в детях любовь к Родине* — балаларда Ватанга мәхәббәт тудыру; 3. *(о животных и растениях)* тәрбияләп үстерү, карап үстерү.

**ВОСПИ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. воспитать.

**ВОСПИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. тәрбияләнү, тәрбия алу; 2. *страд.* тәрбияләнү, тәрбияләп үстерелү; тудырылу, булдырылу.

**ВОСПЛАМЕНИ'ТЬ** *сов.* — 1. кабызу, кабызып җибәрү, дөрләтү, дөрләтеп җибәрү; 2. *(возбудить, одушевить)* рухландыру, дәртләндерү, уяту, дәрт кертү, рухландырып җибәрү, дәртләндереп җибәрү; *слова командира воспламенили бойцов* — командирның сүзләре сугышчыларны рухландырып җибәрде.

**ВОСПЛАМЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. янып китү, кабынып китү, дөрләп китү, дөрт итеп кабынып китү; 2. *перен. (одушевиться)* рухлану, рухланып китү, дәртләнү, дәртләнеп китү.

**ВОСПЛАМЕНЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн. нет* — тиз кабынучанлык, кабынып китүчәнлек.

**ВОСПЛАМЕНЯ'ТЬ** *несов.* — к. воспламенить.

**ВОСПЛАМЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. воспламениться.

**ВОСПО'ЛНИТЬ** *сов.* — тутыру, тулыландыру.

**ВОСПО'ЛНИТЬСЯ** *сов.* — тулу, тулылану.

**ВОСПОЛНЯ'ТЬ** *несов.* — к. восполнить.

**ВОСПОЛНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. восполниться; 2. *страд.* тулыландырылу, тутырылу.

**ВОСПО'ЛЬЗОВАТЬСЯ** *сов.* — файдалану, файдаланып калу; *воспользоваться слу-*

*чаем* — форсаттан файдалану, уңайлы очрактан файдаланып калу.

**ВОСПОМИНА'НИЕ** *ср.* — 1. искә төшерү, хәтергә төшерү; *воспоминание детства* — балачакны искә төшерү; 2. *только мн. (литературное произведение)* истәлекләр. ◇ **Осталось одно воспоминание** — исеме генә калды.

**ВОСПОМИНА'ТЬ** *несов. устар.* — к. вспоминать.

**ВОСПОСЛЕ'ДОВАТЬ** *сов. устар.* — нәтиҗәсе буларак килеп чыгу; *после этого события скоро воспоследовало данное решение* — шул вакыйгадан соң аның нәтиҗәсе буларак менә бу карар килеп чыкты.

**ВОСПРЕПЯ'ТСТВОВАТЬ** *сов.* — комачаулау, тоткарлык ясау, юл куймау, киртә булу, тыю.

**ВОСПРЕТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *устар.* — тыюлы, тыя торган; *воспретительный закон* — тыя торган закон.

**ВОСПРЕТИ'ТЬ** *сов.* — к. воспрещать.

**ВОСПРЕЩА'ТЬ** *несов.* — тыю, юл куймау, рөхсәт итмәү.

**ВОСПРЕЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тыелу, рөхсәт ителмәү.

**ВОСПРЕЩЁННЫЙ** — тыелган, тыюлы.

**ВОСПРИИ'МЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(способность легко воспринимать)* тиз төшенүчәнлек; зирәклек; сизгерлек, тиз отып алучанлык; 2. *(к болезни)* йоктыручанлык, бирешүчәнлек; *восприимчивость к заразным болезням* — йогышлы авыруларга бирешүчәнлек.

**ВОСПРИИ'МЧИВЫЙ** — 1. тиз отып алучан, тиз төшенүчән, зирәк; *восприимчивый ребёнок* — тиз отып алучан бала, зирәк бала; 2. бирешүчән, тиз бирешүчән; *ребёнок, восприимчивый к заразным болезням* — йогышлы авыруларга тиз бирешүчән бала.

**ВОСПРИНИМА'ТЬ** *несов.* — 1. төшенү, аңлау, белү, үзләштерү; 2. каршы алу; *каждое известие о сыне она воспринимала с большой радостью* — улы турында булган һәрбер хәбәрне ул бик шатланып каршы ала иде.

**ВОСПРИНИМА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. аңлану, үзләштерелү; 2. каршы алыну.

**ВОСПРИНЯ'ТЬ** *сов.* — к. воспринимать.

**ВОСПРИЯ'ТИЕ** *ср. псих.* — зиһенгә алу; үзләштерү.

**ВОСПРИЯ'ТЬ** *сов. устар.* — к. воспринимать.

**ВОСПРОИЗВЕДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. (действие)* яңадан барлыкка китерү, яңадан булдыру; 2. *(воссоздание в памяти)* искә төшерү, хәтердә яңарту; 3. копия, күчермә, репродукция; *это не подлинная картина, а её воспроизведение* — бу — картинаның үзе түгел, ә аның күчермәсе.

**ВОСПРОИЗВЕСТИ'** *сов.* — к. воспроизводить.

**ВОСПРОИЗВОДИ'ТЬ** *несов.* — 1. *(производить вновь)* яңадан җитештерү, кабат җитештерү, яңадан булдыру; 2. *(воссоздавать в памяти)* хәтердә яңарту, искә төшерү; 3. кабатлап сөйләү; *воспроизводить чужие мнения* — кеше фикерләрен кабатлап сөйләү; 4. *(создавать, копируя)* (берәр нәрсәгә) карап эшләү, күчереп ясау; 5. *(перепечатывать)* үзгәртмичә яңадан басу, күчереп басу, үзгәртмичә яңадан бастыру.

**ВОСПРОИЗВОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. яңадан булдырылу, яңадан җитештерелү, кабат җитештерелү; 2. хәтердә яңартылу, искә төшерелү; 3. яңадан басылу, үзгәртмичә яңадан басылу, үзгәртмичә яңадан бастырылу.

**ВОСПРОИЗВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — кабат җитештерү.

**ВОСПРОТИ'ВИТЬСЯ** *сов.* — каршы килү, каршылык күрсәтү.

**ВОСПРЯ'НУТЬ** *сов.* — 1. *книж. устар.* сискәнеп китү; 2. *(стать бодрым)* рухлану, рухланып китү, дәртләнү, дәртләнеп китү; күңел күтәрелү, күңел күтәрелеп китү. ◇ **Воспрянуть духом** — күңел күтәрелеп китү. **Воспрянуть от сна** — уяну, уянып китү.

**ВОСПЫЛА'ТЬ** *сов. устар.* — кабынып китү, ярсып китү; *воспылать гневом* — ачудан кабынып китү; ачу кабарып, ярсып китү.

**ВОССЕДА'ТЬ** *несов. книж.* — утыру.

**ВОССЕ'СТЬ** *сов.*: **воссесть на престол** *устар. офиц.* — тәхеткә утыру, патшалык итә башлау.

**ВОССИЯ'ТЬ** *сов. устар. поэт.* — к. засиять.

**ВОССЛА'ВИТЬ** *сов. устар.* — олылау, мактау.

**ВОССЛАВЛЯ'ТЬ** *несов. устар.* — к. восславить.

**ВОССЛАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. устар.* — олылану, макталу.

**ВОССОЕДИНЕ'НИЕ** *ср.* — яңадан кушу, яңадан берләштерү; яңадан кушылу, яңадан берләшү; *воссоединение Западной Украины с УССР* — Көнбатыш Украинаның УССР белән яңадан берләшүе.

**ВОССОЕДИНИ'ТЬ** *сов.* — яңадан кушу, яңадан берләштерү.

**ВОССОЕДИНИ'ТЬСЯ** *сов.* — яңадан кушылу, яңадан берләшү.

**ВОССОЕДИНЯ'ТЬ** *несов.* — к. воссоединить.

**ВОССОЕДИНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. воссоединиться; 2. *страд.* яңадан кушылу, яңадан берләштерелү.

**ВОССОЗДАВА'ТЬ** *несов.* — к. воссоздать.

**ВОССОЗДАВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. воссоздаться.

**ВОССО'ЗДАННЫЙ** — яңадан барлыкка китерелгән, яңадан ясалган, яңартылган.

**ВОССОЗДА'ТЬ** *сов.* — яңадан барлыкка китерү, яңадан булдыру. ◇ **Воссоздать в памяти** — яңадан күз алдына китерү, искә төшерү.

**ВОССОЗДА'ТЬСЯ** *сов.* — яңадан булдырылу, яңадан барлыкка китерелү.

**ВОССТАВА'ТЬ** *несов.* — к. восстать.

**ВОССТА'ВИТЬ** *сов. устар.* — к. восстановить. ◇ **Восставить перпендикуляр** *мат.* — перпендикуляр торгызу.

**ВОССТАВЛЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. восставить.

**ВОССТАНА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. восстановить.

**ВОССТАНА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. восстановиться; 2. *страд.* торгызылу, аякка бастырылу, элекке хәленә кайтарылу.

**ВОССТАНОВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — торгызу...-ы, аякка бастыру...-ы; элекке хәленә кайтару...-ы; *восстановительный период* — (хуҗалыкны) торгызу чоры.

**ВОССТАНОВИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(привести в прежний вид)* торгызу, аякка бастыру, элекке хәленә кайтару; 2. кайтару, үз урынына кую, яңадан алу, кире алу; *восстановить в правах* — хокукын кайтару; *восстановить в должности* — элекке урынына алу, элек эшләгән урынына кую; 3. *(против кого-л.)* дошманлаштыру, каршы кую, дошманлык тойгысын уяту (берәүгә каршы). ◇ **Восстановить в памяти** — хәтердә яңарту, искә төшерү. **Восстановить перпендикуляр** *мат.* — перпендикуляр торгызу. **Восстановить свои силы** — аякка басу, хәл керү (авырудан соң). **Восстановить дружбу** — дуслыкны яңарту.

**ВОССТАНОВИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. элекке хәленә кайту, яңадан ... башлау; *восстановилось движение поездов* — поездлар яңадан йөри башладылар; 2. *(в памяти)* яңару, хәтердә яңару, яңадан искә төшү; 3. кире алу, кире кайтарып алу; *восстановиться в правах* — элекке хокукын кире кайтарып алу.

**ВОССТАНОВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. восстановить.

**ВОССТАНОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. восстанавливаться.

**ВОССТА'ТЬ** *сов.* — 1. *книж. поэт.* тору, уяну; *восстать от сна* — йокыдан тору; 2. каршы күтәрелү; *весь народ восстал на врага* — бөтен халык дошманга каршы күтәрелде; 3. баш күтәрү; *народ восстал против помещиков и капиталистов* — халык алпавытларга һәм капиталистларга каршы баш күтәрде; 4. *(воспротивиться)* каршы төшү.

**ВОСТО'К** *м. мн.* нет — көнчыгыш; *Дальний Восток* — Ерак Көнчыгыш; *Ближний Восток* — Якын Көнчыгыш.

**ВОСТОКОВЕ'Д** *м.* — көнчыгыш илләрнең тарихын һәм культурасын өйрәнүче, ориенталист.

**ВОСТОКОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — көнчыгыш илләрнең тарихын һәм культурасын өйрәнү белеме.

**ВОСТО'РГ** *м.* — 1. зур шатлык; зур куаныч, зур сөенеч; 2. *(восхищение)* соклану, ис китү, таңга калу. ◇ **Быть в восторге** — куану, сөенү. **Быть вне себя от восторга** — шатлыгыннан ни эшләргә белмәү.

**ВОСТОРГА'ТЬ** *несов.* — чиксез шатландыру, куандыру, сөендерү; таңга калдыру.

**ВОСТОРГА'ТЬСЯ** *несов.* — бик нык шатлану, үтә сөенү (куану); соклану, таңга калу, ис китү.

**ВОСТО'РЖЕННО** *нареч.* — 1. сокланып, ис китеп, таңга калып; 2. бик нык мактап.

**ВОСТО'РЖЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. шатлану, куану, сөенү; *детская восторженность* — балаларча шатлану. 2. искитүчәнлек.

**ВОСТО'РЖЕННЫЙ** — 1. искитүчән; *восторженный человек* — искитүчән кеше; 2. шатланып ..., сөенеп ..., куанып ...; *оказать восторженный приём* — шатланып (куанып, сөенеп) каршы алу (кабул итү); 3. исе китеп; *восторженная похвала* — исе китеп мактау. ◇ **Восторженный отзыв о книге** — китап турында бик мактап язылган отзыв.

**ВОСТОРЖЕСТВОВА'ТЬ** *сов.* — өстен чыгу, җиңеп чыгу, җиңү; *правда восторжествует* — хакыйкать җиңеп чыгар.

**ВОСТО'ЧНЫЙ** — көнчыгыш ...-ы; көнчыгыштагы; *восточная граница* — көнчыгыштагы чик; *восточные страны* — көнчыгыш илләре.

**ВОСТРЕ'БОВАТЬ** *сов.* — таләп итеп алу.

**ВОСТРЕПЕТА'ТЬ** *сов. книж. устар.* — калтырый башлау, дерелди башлау.

**ВОСТРИ'ТЬ** *несов. простореч.* — үткенләү.

**ВОСТРО'** *нареч.*: **держать ухо востро** — сак булу, уяу булу.

**ВОСТРОГЛА'ЗЫЙ** *разг.* — үткен күзле, җете күзле.

**ВОСТРОНО'ГИЙ** *разг.* — елдам, елгыр, җитез.

**ВОСТРОНО'СЫЙ** *разг.* — *(о человеке)* кылыч борынлы; *(о лодке)* очлы борынлы.

**ВОСТРУБИ'ТЬ** *сов. устар.* — трубада уйнап җибәрү.

**ВОСТРУ'ХА** *ж. разг., обл. фам.* — бик уңган, җитез; тиктормас.

**ВО'СТРЫЙ** *простореч. обл.* — к. острый.

**ВОСХВАЛИ'ТЬ** *сов. устар.* — бик нык мактау, күкләргә күтәрү.

**ВОСХВАЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. восхвалить.

**ВОСХВАЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. устар.* — бик нык мактялу, күкләргә күтәрелү.

**ВОСХИТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — сокландыргыч, искитәрлек, таңга калырлык.

**ВОСХИТИ'ТЬ** *сов.* — хәйран калдыру, таңга калдыру, сокландыру; *меня восхитила красота этой местности* — мине бу җирнең матурлыгы хәйран калдырды.

**ВОСХИТИ'ТЬСЯ** *сов.* — ис китү, хәйран калу, таңга калу, соклану.

**ВОСХИЩА'ТЬ** *несов.* — к. восхитить.

**ВОСХИЩА'ТЬСЯ** *несов.* — к. восхититься.

**ВОСХО'Д** *м.* — 1. *(о солнце)* чыгу, чыгыш; *(о луне)* калку; 2. *(подниматься вверх)* күтәрелү, менү; 3. *устар. обл.* көнчыгыш. ◇ **На восходе солнца** — кояш чыкканда.

**ВОСХОДИ'ТЬ** *несов.* — 1. *(о солнце)* чыгу; *(о луне)* калку; 2. *(подниматься вверх)* күтәрелү, менү; 3. *(происходить, вести начало от чего-л.)*...-дан килү, барып то-

ташу, башланып китү; *этот памятник восходить к древней культуре* — бу памятник борынгы культурага барып тоташа; *многие обычаи восходят к глубокой древности* — күп кенә гореф-гадәтләр бик борынгы заманнардан килә̣ләр.

**ВОСХОЖДЕ'НИЕ** *ср.* — күтәрелү, менү; *восхождение на Эльбрус* — Эльбруска менү.

**ВОСХОТЕ'ТЬ** *сов. устар.* — тели башлау.

**ВОСЧУ'ВСТВОВАТЬ** *сов. устар.* — хис итү, тою, сизү; тоя башлау; сизә башлау; *восчувствовать великую радость* — зур шатлык хис итү.

**ВОСШЕ'СТВИЕ** *ср.*: **восшествие на престол** *истор.* — тәхеткә утыру, тәхеткә менү, патшалык итә башлау.

**ВОСЬМЕРИ'К** *м.* — 1. сигезле, сигез данәдән (сигез кисәктән) тора торган; 2. *обл.* сигез ат җигелгән арба.

**ВОСЬМЕРИ'ЧНЫЙ** *устар.* — сигез тапкыр арттырылган; сигез кисәктән тора торган. ◇ **„И" восьмеричное** — 1917 елгы орфография реформасына кадәр рус алфавитында „и" хәрефенең исеме.

**ВОСЬМЁРКА** *ж.* — 1. *(цифра)* сигезлек, сигезле цифр; 2. сигез; *восьмёрка самолётов* — сигез самолёт.

**ВОСЬМЕРНО'Й** *разг.* — сигез тапкыр артык, сигез тапкыр зур.

**ВО'СЬМЕРО** — сигез, сигез пар; *восьмеро глаз* — сигез пар күз; *восьмеро мужчин* — сигез ир кеше.

**ВОСЬМИВЕСЕ'ЛЬНЫЙ** — сигез ишкәкле; *восьмивесельная лодка* — сигез ишкәкле көймә.

**ВОСЬМИГРА'ННИК** *м. мат.* — сигезкырлык.

**ВОСЬМИГРА'ННЫЙ** *мат.* — сигез кырлы.

**ВОСЬМИДЕСЯ'ТЫЙ** — сиксәненче.

**ВОСЬМИДНЕ'ВНЫЙ** — сигез көнлек.

**ВОСЬМИЗНА'ЧНЫЙ**: **восьмизначное число** *мат.* — сигез урынлы сан.

**ВОСЬМИКЛА'ССНИК** *м.*, **ВОСЬМИКЛА'ССНИЦА** *ж.* — сигезенче класс укучысы.

**ВОСЬМИЛЕ'ТНИЙ** — 1. сигез еллык; *восьмилетний срок* — сигез еллык срок; 2. *(о возрасте)* сигез яшьлек; *восьмилетний ребёнок* — сигез яшьлек бала.

**ВОСЬМИНО'Г** *м. зоол.* — сигезаяк, спрут.

**ВОСЬМИСЛО'ЖНЫЙ** — сигез иҗекле.

**ВОСЬМИСО'ТЫЙ** — сигез йөзенче.

**ВОСЬМИСТИ'ШЬЕ** *ср.* — сигез юллы шигырь.

**ВОСЬМИСТО'ПНЫЙ** — сигез стопалы (шигырь).

**ВОСЬМИУГО'ЛЬНИК** *м. мат.* — сигезпочмак.

**ВОСЬМИУГО'ЛЬНЫЙ** *мат.* — сигез почмаклы.

**ВОСЬМИЧАСОВО'Й** — сигез сәгатьлек; *восьмичасовой рабочий день* — сигез сәгатьлек эш көне.

**ВОСЬМО'Й** — сигезенче.

**ВОСЬМУ'ХА, ВОСЬМУ'ШКА** *ж. разг.* — 1. *устар. (вес)* әчмуха; 2. *(формат)* сигездән бер өлеш.

**ВОТ** *частица* — 1. менә, әнә; *вот здесь* — менә монда, менә биредә; *вот вам пример* — менә сезгә бер мисал; *вот этот человек* — менә шушы кеше; *вот он там* — әнә ул анда; 2. менә; *вот вас-то мне и надо* — менә миңа сез кирәк тә идегез; *вот хорошо!* — менә әйбәт! ◇ **Вот тебе и на! Вот так так! Вот тебе и раз!** — менә сиңа кирәк булса! **Вот и вся недолга, вот тебе и сказ** — менә озын сүзнең кыскасы шул. **Вот то-то (же)** — менә бөтен фаҗига да шунда. **Вот поди же ты** — бернәрсә эшләп булмый.

**ВОТ-ВОТ** *нареч.* — 1. *(вот именно)* менә шулай, шулай шул; нәкъ; 2. *(только что)* әле генә, хәзер генә; менә-менә.

**ВОТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — тавыш бирү (парламентта, җыелышта).

**ВОТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — тавышка куелу.

**ВОТКА'ТЬ** *сов.* — чүпләмләп туку, чүпләмләп сугу.

**ВОТКНУ'ТЬ** *сов.* — кадау, чәнчү, кадап кую, чәнчеп кую, кагып кую; *воткнуть кол в землю* — җиргә казык кагып кую.

**ВОТКНУ'ТЬСЯ** *сов.* — чәнчелү, кадалу, кадалып керү.

**ВО'ТУМ** *м. полит.* — вотум (буржуаз илләрдә: тавыш бирү юлы белән чыгарылган карар); *вотум доверия* — ышаныч вотумы, ышаныч белдерү (хөкүмәтнең яки министрның эшен яхшы дип табу); *вотум недоверия* — ышанмау вотумы (хөкүмәтнең яки министрның эшен парламентта тавыш бирү юлы белән канәгатьләнерлек түгел дип табу).

**ВО'ТЧИНА** *ж. истор.* — вотчина (борынгы заманда Москва Русенда эре җир биләүченең — князьнең, боярның ата-бабадан мирас булып килгән имениесе, җире).

**ВО'ТЧИННИК** *м. истор.* — вотчина хуҗасы, вотчина биләүче.

**ВО'ТЧИННЫЙ** *истор.* — вотчина ...-ы; *вотчинное право* — вотчина хокукы.

**ВОТЩЕ'** *нареч. устар.* — юкка, бушка, әрәмгә, зрә, юкка гына.

**ВОТЯКИ'** *устар.* — арлар (удмуртларны элек шулай атаганнар).

**ВОХО'ТКУ** *нареч. простореч.* — 1. бик теләп, авыз суы корып, хуш күреп, яратып, ләззәтләнеп; *поел вохотку суп* — ашны бик теләп ашадым; 2. ...-сым килә; *мне вохотку прогуляться сейчас* — хәзер йөреп кайтасым килә.

**ВОЦАРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *истор.* тәхеткә утыру, тәхеткә менү. 2. *перен.* урнашу; *воцарилась полная тишина* — тулы тынлык (тынычлык) урнашты.

**ВОЦАРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. воцариться.

**ВОШЬ** *ж.* — бет.

**ВОЩА'НКА** *ж.* — 1. *(бумага)* балавызлы кәгазь; *(ткань)* балавызлы тукыма; 2. *(кусок воска)* балавыз кисәге; 3. *(пустая ячейка)* буш кәрәз.

**ВОЩАНО'Й, ВОЩА'НЫЙ** — 1. *(сделанный из воска)* балавыздан ясалган; 2. балавызлы, балавызланган.

**ВОЩИ'НА** *ж.* — 1. *(пустые соты)* кәрәз, балсыз кәрәз; 2. *(воск)* эретелгән балавыз.

**ВОЩИ'ТЬ** *несов.* — 1. балавызлау, балавыз сөртү, балавыз белән ялтырату; *вощить пол* — идәнне балавыз белән ялтырату; 2. *(снабжать улей вощиной)* кәрәз кую.

**ВОЩИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. балавызлану, балавыз сөртелү; балавыз белән ялтыратылу; 2. кәрәз куелу.

**ВОЯ'Ж** *м.* — сәяхәт, сәфәр.

**ВОЯЖЁР** *м.* — 1. *шутл. ирон.* сәяхәтче, илгизәр; 2. *дореволь.* заказлар җыеп йөрүче прика чик, коммивояжер.

**ВОЯЖИ'РОВАТЬ** *несов. шутл. ирон.* — сәяхәт итү, ил гизү, сәфәр йөрү.

**ВОЯ'КА** *м. разг. шутл.* — сугышчы, сугыш чукмары.

**ВПАДА'ТЬ** *несов.* — 1. к. впасть; 2. кою, кушылу; *Волга впадает в Каспийское море* — Волга Каспий диңгезенә коя; *Кама впадает в Волгу* — Кама Волгага кушыла; 3. керү; *впадать в синий цвет* — зәңгәр төскә керү. ◇ **Впадать в детство** — балалар акылы керү (картайгач). **Впадать в противоречие** — үз енә үзе каршы килү.

**ВПАДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(о реке)* кою, кушылу; 2. *(устье рек)* елга тамагы, койган урыны, инеш тамагы; *Город Горький стоит при впадении Оки в Волгу* — Горький шәһәре Оканың Волгага койган урынында утыра.

**ВПА'ДИНА** *ж.* — чокыр, батынкы урын.

**ВПА'ИВАТЬ** *несов.* — к. впаять.

**ВПА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — паять ителү, эретеп эченә ябыштырылу.

**ВПА'ЛЗЫВАТЬ** *многокр. разг.* — к. вползать.

**ВПА'ЛЫЙ** — эчкә баткан, эчкә батып кергән, батынкы; *впалые щёки* — батынкы яңаклар; *впалые глаза* — эчкә баткан күзләр.

**ВПА'РХИВАТЬ** *несов.* — к. впорхнуть.

**ВПАСТЬ** *сов.* — 1. бату, эчкә бату; *глаза у больного впали* — авыруның күзләре эчкә баткан; 2. *перен.* төшү, бирелү; *он впал в отчаяние* — ул өметсезлеккә бирелде; *впасть в сомнение* — шиккә төшү. ◇ **Впасть в беду** — бәләгә эләгү. **Впасть в бедность** — ярлыга калу, ярлылыкка төшү.

**ВПАЯ'ТЬ** *сов.* — паять итеп ябыштыру.

**ВПЕРВИ'НКУ** *нареч. простореч. обл.* — беренче тапкыр, беренче мәртәбә, беренче кат.

**ВПЕРВО'Й** *нареч. простореч.* — беренче тапкыр, беренче кат, беренче мәртәбә.

**ВПЕРВЫ'Е** *нареч.* — беренче тапкыр, беренче мәртәбә, беренче тапкыр буларак.

**ВПЕРЕБИ'ВКУ** *нареч. простореч.* — берсен-берсе бүлә-бүлә, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә; *заговорили вперебивку* — берсен-берсе бүлә-бүлә сөйли башладылар.

**ВПЕРЕБО'Й** *нареч. простореч.* — бүлдерә-бүлдерә, бер-берсен узышып; *закричали вперебой* — бер-берсен узышып кычкыра башладылар.

**ВПЕРЕВА'ЛКУ** *нареч.* — ава-түнә, алпан-тилпән (әле бер якка, әле икенче якка ауна клап).

**ВПЕРЕГИ'Б** *нареч.* — иелеп, бөгелеп.

**ВПЕРЕГОНКИ', ВПЕРЕГО'НКУ** *нареч. обл.* — куышып, куыша-куыша, узыша-узыша, узышып, узышып-узышып.

**ВПЕРЁД** *нареч.* — 1. алга; *идти вперёд* — алга бару; 2. алдан; *заплатить вперёд* — алдан түләү; 3. элек, башта, әүвәл, алдан; *вперёд подумай, а потом скажи* — элек уйла, аннан соң әйт; 4. *разг.* киләчәктә, моннан соң; моннан ары; *это мне вперёд наука* — киләчәктә бу миңа сабак булыр. ◇ **Забегать вперёд** — ашыгу.

**ВПЕРЕДИ'** I — 1. алдан, алда, каршыда; *идти впереди* — алдан бару; *впереди показался лес* — алда (каршыда) урман күренде; 2. киләчәктә, моннан соң, алда; *что случится с ними впереди* — киләчәктә аларга нәрсә булыр; 3. *в знач. сказ.* алда; *наше будущее впереди* — безнең киләчәгебез алда.

**ВПЕРЕДИ'** II *предлог с род. п.* — алдыннан, алдында; *он ехал впереди колонны* — ул колонна алдыннан бара иде.

**ВПЕРЕМЕ'ЖКУ** *нареч. разг.* — алмаштилмәш, алмашлап, алмашлашып.

**ВПЕРЕМЕ'ШКУ** *нареч. разг.* — аралаш; аралаштырып, буташтырып, бутап.

**ВПЕРЕРЫ'В** *нареч. простореч.* — к. наперерыв.

**ВПЕРЕ'ТЬ** *сов. разг. вульг.* — 1. рөхсәтсез керү; 2. *(внести с трудом)* көчкә алып керү.

**ВПЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — рөхсәтсез килеп керү.

**ВПЕРЕХВА'Т** *нареч.* — 1. әйләндереп алып, уратып; *вяжи вперехват* — уратып бәйлә; 2. юлына аркылы, юлын кисеп; *забегай вперехват* — юлын кисеп йөгер, юлына аркылы йөгер.

**ВПЕРИ'ТЬ** *сов.* — *(взор)* текәлү, текәлеп карау; *(внимание)* юнәлдерү.

**ВПЕРИ'ТЬСЯ** *сов.* — текәлеп карый башлау, сокланып карый башлау.

**ВПЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. вперить.

**ВПЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. впериться; 2. *страд.* текәлдерелү, юнәлдерелү.

**ВПЕЧАТЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. тәэсир, эз; 2. *(воздействие, влияние)* йогынты, тәэсир. ◇ **Впечатления детства** — балачак истәлекләре. **Создаётся впечатление** — булып күренә, ...-сыман булып күренә. **По первому впечатлению** — беренче караштa.

**ВПЕЧАТЛИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәэсиргә тиз бирелү, тиз әсәрләнүчәнлек; сизгерлек, йомшак күңеллелек.

**ВПЕЧАТЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** — тәэсиргә тиз бирелүчән, йомшак күңелле, сизгер.

**ВПЕЧАТЛЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәэсир калдыручанлык.

**ВПЕЧАТЛЯ'ТЬ** *несов.* — тәэсир калдыру, эз калдыру, тирән тәэсир калдыру.

**ВПИВА'ТЬ** *несов.* — сеңдерү, суыру. ◇ **Впивать звуки музыки** *перен.* — музыка тавышларын йотылып тыңлау. **Жадно впивать впечатления** — тәэсирләргә бик нык бирелү.

**ВПИВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. впиться.

**ВПИ'КУ** *нареч. разг.* — үч итеп, ачу итеп, ачудан.

**ВПИРА'ТЬ** *несов. разг. вульг.* — к. впереть.

**ВПИРА'ТЬСЯ** *несов.* — к. впереться.

**ВПИ'САННЫЙ** — 1. арасына (эченә) язылган; арасына язып куелган (төшеп калган сүз); 2. *мат.* камаулы, эчкә сызылган; *вписанный круг* — камаулы түгәрәк.

**ВПИСА'ТЬ** *сов.* — 1. язып кую, теркәү, кертеп язу, арага язу; *вписать пропущенные слова* — төшеп калган сүзләрне арага язу; 2. *мат.* эченә сызу; *вписать треугольник в окружность* — өчпочмакны түгәрәк эченә сызу.

**ВПИСА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(в текст, список)* язылу, теркәлү; 2. *мат.* эченә сызылу, камалу.

**ВПИ'СЫВАТЬ** *несов.* — к. вписать.

**ВПИ'СЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. вписаться; 2. *страд.* язып куелу, эченә сызылу.

**ВПИТА'ТЬ** *сов.* — 1. сеңдерү, сеңдереп бетерү, суырып бетерү; *земля быстро впитала всю влагу* — җир барлык дымны бик тиз суырып бетерде; 2. *перен.* үзләштерү, сеңдерү, алу; *впитать культуру* — культураны үзләштерү.

**ВПИТА'ТЬСЯ** *сов.* — сеңү, сеңеп бетү.

**ВПИ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. впитать.

**ВПИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. впитаться; 2. *страд.* сеңдерелү.

**ВПИТЬ** *сов.* — к. впивать.

**ВЫДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — ясалу, эшләнү, эшләп чыгарылу; *на этой фабрике выделываются валенки* — бу фабрикада киез итекләр эшләп чыгарыла.

**ВЫДЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. выделить.

**ВЫДЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выделиться 1, 3; 2. аерылып тору; *он выделяется своей храбростью* — ул үзенең кыюлыгы белән аерылып тора; 3. *страд.* аерып чыгарылу, эшләп чыгарылу.

**ВЫ'ДЕРГАТЬ** *сов.* — 1. суырып бетерү; *выдергать все больные зубы* — барлык авырткан тешләрне суырып бетерү; 2. йолкып бетерү; *выдергать лён* — җитенне йолкып бетерү.

**ВЫДЁРГИВАТЬ** *несов.* — 1. к. выдергать; 2. к. выдернуть. ◇ **Выдёргивать цитаты** — аннан-моннан цитаталар алу.

**ВЫДЁРГИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выдернуться; 2. *страд.* (*о растении*) йолкыну, йолкып бетерелү; (*о гвозде, зубе*) суырылу, суырып бетерелү, суырып чыгарылу.

**ВЫ'ДЕРЖАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. тотнаклылык, сабырлык, салкын канлылык, үзен-үзе тота алучанлык; *выдержанность характера* — характерының тотнаклылыгы; 2. эзлеклелек, тотрыклылык, турылыклы булу; *идеологическая выдержанность* — идеологик яктан тотрыклылык (турылыклы булу).

**ВЫ'ДЕРЖАННЫЙ** — 1. озак сакланып сыйфаты яхшыртылган; *выдержанный сыр* — озак сакланып сыйфаты яхшыртылган сыр; 2. *перен.* тотнаклы, сабыр, үзен-үзе тота белүче, салкын канлы; *выдержанный человек* — тотнаклы кеше; 3. эзлекле; *выдержанный стиль* — эзлекле стиль; 4. тотнаклы, турылыклы; *политически выдержанный человек* — политик яктан тотнаклы кеше.

**ВЫ'ДЕРЖАТЬ** *сов.* — 1. чыдау, түзү, күтәрү; *этот лёд выдержит пешеходов* — бу боз җәяүлеләрне күтәрер; 2. бирешмәү, чыдау, җиңелмәү, җиңеп чыгу; *выдержать бурю* — давылга бирешмәү; *выдержать тяжёлые испытания* — авыр сынауларны җиңеп чыгу; 3. *разг.* үзен тота алу, үзен тыя алу, үзен тотып калу, чыдый алу; *не выдержал и заплакал* — чыдый алмады, елап җибәрде; 4. тоту; *выдержать преступника целый день под арестом* — җинаятьчене көне буе ябып тоту; 5. тотып тору; *выдержать товар* — товарны тотып тору (яшереп, саклап тору); 6. озак саклап (тотып) сыйфатын яхшырту; *выдержать вино* — озак саклап (тотып) кызыл аракының сыйфатын яхшырту. ◇ **Выдержать характер** — нык тору, бирешмәү. **Выдержать роль** — үзен оста тоту. **Выдержать несколько изданий** — берничә тапкыр басылып чыгу (китап турында). **Машина выдержала испытание** — машина яраклы булып чыкты.

**ВЫДЕ'РЖИВАТЬ** *несов.* — к. выдержать. ◇ **Не выдерживает критики** *перен.* — тәнкыйтьтән түбән, начар, бернигә яраксыз, яраклы түгел. **Выдерживать срок** — срогы житкәнче көтү. **Выдерживать взгляд** — күзне алмый карап тору.

**ВЫДЕ'РЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — тотылу, саклану; *вино выдерживается в погребах* — кызыл аракы базларда саклана (билгеле вакыт буена).

**ВЫ'ДЕРЖКА** I *ж.* — өземтә, китерелгән өзек, цитата; *выдержка из книги* — китаптан китерелгән (алынган) өземтә. ◇ **Взять на выдержку** (*что-л.*) — сайламыйча алу (китерү, уку), кайсы төше туры килсә, шуны алу (уку, китерү).

**ВЫ'ДЕРЖКА** II *ж. мн.* нет — 1. (*самообладание*) чыдамлылык, түземлелек, тотнаклылык, тотрыклылык, сабырлык, үзенең тотучанлык; үзен тота алучанлык;

2. (*выносливость*) ныклык, чыдамлык, түземлек.

**ВЫ'ДЕРНУТЬ** *сов.*— суыру, суырып алу (чыгару), йолкып чыгару, тартып алу; *выдернуть гвоздь* — кадакны суырып алу.

**ВЫ'ДЕРНУТЬСЯ** *сов.*— суырылып чыгу, чыгу; *нитка выдернулась из ушка иголки* — җеп энә күзеннән чыккан.

**ВЫДИРА'ТЬ** *несов. разг.*— к. выдрать 1.

**ВЫДИРА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— к. выдраться.

**ВЫ'ДОИТЬ** *сов. с.-х.* — савып бетерү.

**ВЫ'ДОЛБИТЬ** *сов.*— 1. чокып (уеп) ясау, чоку, казу, чокып тишү; 2. *перен. разг. вульг.* ятлау, яттан бикләү; *выдолбить таблицу умножения* — тапкырлау таблицасын ятлау.

**ВЫ'ДОХНУТЬ** *сов.*— к. выдыхать.

**ВЫ'ДОХНУТЬСЯ** *сов.*— к. выдыхаться.

**ВЫ'ДРА** *ж.*— 1. *зоол.* (*речная*) кама; (*морская*) камчат; 2. (*мех*) кама, кама тиресе; камчат, камчат тиресе.

**ВЫ'ДРАТЬ** *сов. разг.*— 1. (*вырвать*) ертып алу, кубарып алу, йолкып алу, куптарып алу; 2. (*наказать поркой*) суктыру, кыйнау, чыбыклау, чыбык белән суктыру. ◇ **Выдрать за уши** — колагын бору.

**ВЫ'ДРАТЬСЯ** *сов. разг.*— ерынып чыгу, көчкә чыгу, кыенлык белән чыгу, читенлек белән чыгу.

**ВЫДРЁНОК** *м.* (*мн.* выдрята) *зоол.*— кама баласы, камчат баласы.

**ВЫ'ДРЕССИРОВАТЬ** *сов.*— дрессировать итү, өйрәтү, өйрәтеп җиткерү.

**ВЫ'ДТИ** — к. выйти.

**ВЫ'ДУБИТЬ** *сов.*— кайры белән иләү (тирене), дуплап иләү, (тирене) дуплау.

**ВЫДУВА'ЛЬЩИК** *м.* — өрүче, пыяла өрүче (пыяла заводында).

**ВЫДУВА'ТЬ** *несов.*— к. выдуть.

**ВЫДУВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. өреп чыгарылу; 2. (*изготовляться посредством дутья*) өреп ясалу (шешә турында).

**ВЫДУВНО'Й** *спец.*— өреп ясалган; *выдувное стекло* — өреп ясалган пыяла.

**ВЫ'ДУДИТЬ** *сов. обл.*— к. дудить.

**ВЫ'ДУМАННЫЙ** — 1. уйлап чыгарылган; уйлап табылган; 2. (*вымышленный*) уйдырма, ялган, булмаган.

**ВЫ'ДУМАТЬ** *сов.*— 1. (*придумать*) уйлап табу, уйлап чыгару; 2. (*налгать, сфантазировать*) ялганлау, уйдырма кору, үзеннән чыгарып сөйләү. ◇ **Не выдумай** *разг.*— уйлап та карама, башыңа да китермә (берәр нәрсә эшләргә). **Пороха не выдумает** *разг.*— акылга уртача, әллә кем түгел, акылы белән аерылмый.

**ВЫ'ДУМКА** *ж.*— 1. (*затея*) уйлап чыгарылган нәрсә; 2. (*вымысел*) уйдырма, ялган.

**ВЫ'ДУМЩИК** *м.*, **ВЫ'ДУМЩИЦА** *ж. разг.*— 1. (*враль*) алдакчы, ялганчы; 2. (*затейник*) мәзәкче, уенчак (төрле уеннар уйлап чыгаручы).

**ВЫДУ'МЫВАТЬ** *несов.*— к. выдумать. ◇ **Не выдумывай** — юкны сөйләмә.

**ВЫДУ'МЫВАТЬСЯ** *несов.*— уйлап чыгарылу; *буржуазной печатью выдумываются разные небылицы о Советском Союзе* — буржуаз матбугат тарафыннан Советлар Союзы турында төрле тузга язмаган нәрсәләр уйлап чыгарыла.

**ВЫ'ДУТЬ** *сов.*— 1. өреп чыгару; өреп суыту; *в комнате было тепло, но за ночь ветром выдуло* — бүлмәдә җылы иде, ләкин төн буе җил өреп суыткан; 2. (*изготовить дутьём*) өреп ясау; 3. *простореч.* (*выпить до дна*) эчеп бетерү, төбен ялтырату. ◇ **Выдуть огонь** *простореч.*— (өреп) ут үрләтү, ут көйрәтеп җибәрү, ут тергезү. **Выдуть доменную печь** *горн. тех.* — домна мичен сүндерү.

**ВЫ'ДУШИТЬ** *сов. разг.*— сөртеп бетерү, сибеп бетерү (исле майны).

**ВЫДЫХА'ТЕЛЬНЫЙ** — тын чыгару...-ы, сулыш чыгару...-ы; *выдыхательное движение* — сулыш чыгару хәрәкәте.

**ВЫДЫХА'ТЬ** *несов.*— тын чыгару, сулыш чыгару.

**ВЫДЫХА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. (*терять запах, крепость*) исе бетү, тәме бетү; айнү, искерү, көче бетү; 2. *перен. разг.* (*терять силу, бодрость*) көч бетү, хәл бетү, хәлдән таю, көчен югалту; дәрт бетү, дәрман бетү.

**ВЫЕДА'ТЬ** *несов.*— 1. (*выгрызать*) уртасын ашау, эчен ашау, эчен ашап керү, эчен ашап бетерү; 2. (*о едких веществах*) яндыру, ашау, кисү; *некоторые краски выедают материю* — кайбер буяулар материяне кисәләр (ашыйлар).

**ВЫЕДА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— 1. эче ашалу, уртасы ашалу; 2. ашалу, киселү, яндырылу.

**ВЫ'ЕДЕННЫЙ** — эче ашалган, эче киселгән; ашап бетерелгән, кисеп бетерелгән. ◇ **Не сто́ит выеденного яйца** *погов.*— сукыр бер тиен дә тормый (әһәмиятсез, берниндн кыйммәте юк).

**ВЫ'ЕЗД** *м.* — 1. *только ед.* (*действие*) китү, чыгып китү; *выезд за границу* — чит илгә чыгып китү; 2. чыгу урыны, чыгу юлы, капка; *выезд из города охранялся караулом* — шәһәрдән чыгу урынын каравыл саклый иде; 3. *с.-х.* чыгыш; *пробный выезд* — сынау чыгышы (чәчүгә хәзерлекне сынау өчен); 4. *устар.* (*экипаж с лошадьми*) ат-арба.

**ВЫ'ЕЗДИТЬ** *сов.*— өйрәтү, атланып йөрергә өйрәтү, җигеп йөрергә өйрәтү.

**ВЫ'ЕЗДИТЬСЯ** *сов.* — җигелеп йөрергә өйрәнү (ат турында).

**ВЫЕЗДНО'Й** — 1. чыгу...-ы; *выездные ворота* — чыгу капкасы; 2. *устар.* кешелеккә кия торган; *выездное платье* — кешелеккә кия торган күлмәк. ◇ **Выездная сессия суда** — судның күчмә сессиясе (судны гадәттә була торган урыннан икенче урынга барып үткәрү).

**ВЫЕЗЖА'ТЬ** I *несов.* — **1.** чыгып китү, чыгу; *выезжать из деревни* — авылдан чыгып китү; **2.** (*покидать квартиру*) китү, квартирадан китү; **3.** *перен. разг.* кеше исәбенә көн күрү, кеше җилкәсендә яшәү, кеше аркасында яшәү; берәр нәрсә аркасында отып чыгу.

**ВЫЕЗЖА'ТЬ** II *несов.* — к. выездить.

**ВЫЕЗЖА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — өйрәтелү, җигеп йөрергә өйрәтелү, атланып йөрергә өйрәтелү.

**ВЫ'ЕМ** *м. разг.* — уем, уемты, уеп алынган урын.

**ВЫ'ЕМКА** *ж.* — **1.** *только ед.* (*действие*) к. вынуть; **2.** (*вырез, углубление*) уем, уенты, уеп алынган урын.

**ВЫЁМНЫЙ** *простореч.* — алынмалы; *выёмные рамы* — алынмалы рамнар.

**ВЫ'ЕСТЬ** *сов.* — к выедать. ◇ **Глаза выело дымом** *разг.* — төтен күзне ачыттырды.

**ВЫ'ЕХАТЬ** *сов.* — к. выезжать I.

**ВЫЖА'РИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. выжарить.

**ВЫЖА'РИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. выжариться.

**ВЫ'ЖАРИТЬ** *сов. простореч.* — (*о посуде*) кыздыру; (*о кушанье*) кыздыру, кыздырып пешерү.

**ВЫ'ЖАРИТЬСЯ** *сов. простореч.* — **1.** (*о посуде*) кызу; **2.** (*о кушанье*) кызу, кызып пешү. ◇ **Выжариться на солнце** — кояшта кызынып каралып бетү.

**ВЫ'ЖАТЬ** I *сов.* — **1.** кысып чыгару, сыгып чыгару, изеп чыгару; *выжать из лимона сок* — лимон суын сыгып чыгару; **2.** сыгу; *выжать бельё* — кер сыгу; **3.** (*вытеснить*) кысрыклап чыгару, арадан чыгару. ◇ **Выжать последние соки (последние силы)** — канын сыгу, җелеген суыру. **Он выжал левой рукой 50 кг** — ул сул кулы белән 50 кг күтәрде.

**ВЫ'ЖАТЬ** II *сов.* — **1.** урып бетерү; *выжать два гектара* — ике гектарны урып бетерү; **2.** ура алу; *она и пяти снопов не выжнет* — ул биш көлтә дә ура алмас.

**ВЫ'ЖАТЬСЯ** *сов. разг.* — **1.** (*о жидкости*) сыгылып чыгу, сыгылып чыгып бетү; **2.** сыгылу; *бельё хорошо выжалось* — кер яхшы сыгылды.

**ВЫ'ЖДАТЬ** *сов.* — көтеп алу; *выждать удобный случай* — уңай вакытны көтеп алу.

**ВЫ'ЖЕЛТИТЬ** *сов.* — сарыга буяу, сарыга буяп чыгу.

**ВЫ'ЖЕЛТИТЬСЯ** *сов. разг.* — сарыга буялу, сары буяу белән буялу; сарыга пычрану, сарыга пычранып бетү.

**ВЫ'ЖЕРЕБ** *м. с.-х.* — үрчем, үрчем бирү (колыннар турында гына әйтелә).

**ВЫ'ЖЕЧЬ** *сов.* — **1.** (*истребить огнём, жаром*) яндырып бетерү, яндырып үтереп бетерү; **2.** (*очистить обжиганием*) яндырып чистарту; **3.** яндырып (тамга) салу; *выжечь клеймо* — яндырып тамга салу; **4.** *мед.* яндыру, көйдерү, яндырып дәвалау.

**ВЫЖИВА'ТЬ** *несов.* — к. выжить.

**ВЫЖИВА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — куылу, куып чыгарылу, китәргә мәҗбүр ителү.

**ВЫ'ЖИГА** — **1.** *ж. с.-х. обл.* ышна, янык (урман яндырып арчылган җир); **2.** *м.* и *ж. простореч.* (*опытный плут*) кырык алдар, оста алдакчы, хәйләкәр.

**ВЫЖИГА'ТЬ** *несов.* — к. выжечь. ◇ **Выжигать по дереву** — агачка көйдереп рәсем төшерү.

**ВЫЖИГА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — **1.** яндырып бетерелү, көйдереп бетерелү; **2.** яндырып чистартылу; **3.** *мед.* яндырып дәвалану, яндырылу, көйдерелү; **4.** көйдереп сугылу (тамга).

**ВЫЖИДА'ТЕЛЬНЫЙ** — көтеп тору...-ы; сагалап тору...-ы; *выжидательная политика* — көтеп тору политикасы (уңайлы вакытны көтеп эш итүгә корылган политика).

**ВЫЖИДА'ТЬ** *несов.* — көтеп тору, сагалап тору; *выжидать удобного случая* — уңайлы вакытны көтеп тору.

**ВЫЖИМА'ЛА** *м. разг. вульг.* — кан эчүче, канечкеч, эксплуататор, изүче.

**ВЫЖИМА'ТЬ** *несов.* — к. выжать I.

**ВЫЖИМА'ТЬСЯ** *несов.* — к. выжаться.

**ВЫ'ЖИМКИ** *ед. нет* — сыгынты; түп; *конопляные выжимки* — киндер түбе.

**ВЫЖИНА'ТЬ** *несов. с.-х.* — к. выжать II.

**ВЫЖИНА'ТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.* — урылу, урып алыну.

**ВЫЖИРА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. выжрать.

**ВЫЖИРА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — ашап бетерелү, беткәнче ашалу.

**ВЫ'ЖИТЬ** *сов.* — **1.** (*остаться в живых*) сау калу, исән калу; **2.** *разг.* тору, яшәү; *он выжил в доме около года* — ул өйдә бер ел чамасы торды; **3.** *разг.* (*выгнать*) кысрыклап чыгару, куып чыгару, китәргә мәҗбүр итү, чыгарып җибәрү, куып җибәрү. ◇ **Выжить из ума** *разг.* — акыл зәгыйфьләнү (картаю сәбәпле).

**ВЫ'ЖЛЕЦ** *м.*, **ВЫ'ЖЛИЦА** *ж. охот.* — ау эте.

**ВЫЖЛЯ'ТНИК** *м. охот. устар.* — эт караучы (ау этләрен йөртүче аучы).

**ВЫ'ЖРАТЬ** *сов. простореч.* — ашап бетерү, беткәнче ашау; *собаки выжрали у падали внутренности* — этләр үләксәнең эчен ашап бетергәннәр.

**ВЫ'ЗВАТЬ** *сов.* — **1.** чакырып чыгару, чакыру; *вызвать товарища из дома* — иптәшне өйдән чакырып чыгару; *вызвать врача* — врач чакыру; *вызвать к доске* — тактага чыгару; **2.** чакыру; *вызвать на социалистическое соревнование* — социалистик ярышка чакыру; **3.** китереп чыгару, тудыру, китерү, кузгату; *вызвать неудовольствие* — ризасызлык тудыру; *вызвать рвоту* — косасыны китерү; *вызвать аппетит* — ашыйсыны китерү; *вызвать гнев* — ачу кузгату. ◇ **Вызвать на откровенность** — эч серләрен ачып бирергә мәҗбүр итү. **Вызвать огонь противника** *воен.* — ут ачарга мәҗбүр итү (дошманның яшерен

позицияләрен белү өчен). **Вызвать в памяти** — искә төшерү.

**ВЫ'ЗВАТЬСЯ** *сов.*— өстенә алу, үзе теләп алыну; үзен тәкъдим итү,...-рга булу; *он вызвался меня проводить* — ул мине озатырга булды.

**ВЫ'ЗВЕЗДИТЬ** *сов. безл.:* **уже давно вызвездило** — күк йөзе инде күптән йолдызлар белән капланды, күптән инде йолдызлар калыкты.

**ВЫ'ЗВОЛИТЬ** *сов. простореч.*— коткару, азат итү, котылдыру, йолу, йолып алу; *вызволить из беды* — бәладән коткару.

**ВЫЗВОЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.*— к. вызволить.

**ВЫЗВОЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — коткарылу, азат ителү, котылдырылу.

**ВЫ'ЗВОНИТЬ** *сов. спец.*— кыңгырау тавышларыннан көй чыгару.

**ВЫЗДОРА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — терелү, терелеп килү; *больной уже выздоравливает* — авыру инде терелеп килә.

**ВЫ'ЗДОРОВЕТЬ** *сов.*— терелү, савыгу, сәламәтләнү; терелеп җитү, савыгып җитү, аякка басу.

**ВЫ'ЗЕЛЕНИТЬ** *сов.*— яшелгә буяу, яшелгә буяп чыгу.

**ВЫ'ЗЕЛЕНИТЬСЯ** *сов. разг.*— яшелгә пычранып бетү.

**ВЫ'ЗИМОВАТЬ** *сов. разг. обл.*— кышлап чыгу.

**ВЫЗНАВА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. вызнать.

**ВЫЗНАВА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— төпченеп беленү, сорашып беленү, белеп бетерелү.

**ВЫ'ЗНАТЬ** *сов. разг.*— төпченеп белү, сорашып белү; *вызнай все подробности* — барысын да сорашып бел.

**ВЫ'ЗОВ** *м.* — **1.** *(действие)* чакыру, чакырып китерү; *вызов врача на дом* — врачны өйгә чакыру; **2.** *(явочный документ)* чакыру кәгазе; **3.** өндәү, чакыру; *вызов на социалистическое соревнование*— социалистик ярышка чакыру; **4.** каршы чыгу; *это звучит как вызов общественности* — бу җәмәгатьчелеккә каршы чыгу булып яңгырый.

**ВЫЗОЛА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*—к. вызолотить.

**ВЫЗОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. вызолотиться.

**ВЫ'ЗОЛОТИТЬ** *сов.* — алтын йөгертү, алтынгаману.

**ВЫ'ЗОЛОТИТЬСЯ** *сов.*— алтын йөгертелү, алтынга манылу.

**ВЫЗРЕВА'ТЬ** *несов.*— к. вызреть.

**ВЫ'ЗРЕТЬ** *сов.*— өлгерү, пешү, өлгереп җитү, пешеп җитү.

**ВЫЗУ'БРИВАТЬ** I *несов.*— к. вызубрить I.

**ВЫЗУ'БРИВАТЬ** II *несов.*— к. вызубрить II.

**ВЫЗУ'БРИВАТЬСЯ** I *несов. страд.*— тешләндерелү, үтмәсләндерелү.

**ВЫЗУ'БРИВАТЬСЯ** II *несов. страд.*— мәгънәсенә төшенмичә ятлану, өйрәнелү.

**ВЫ'ЗУБРИТЬ** I *сов.*— тешләндерү, үтмәсләндерү, үтмәсләндереп бетерү; *вызубрить топор* — балтаны тешләндереп бетерү.

**ВЫ'ЗУБРИТЬ** II *сов.*— мәгънәсенә төшенмичә ятлау, өйрәнү.

**ВЫЗЫВА'ТЬ** *несов.*— к. вызвать.

**ВЫЗЫВА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. вызваться; **2.** *страд.* чакырылу, чакырып чыгарылу; **3.** ...-дән булу, ... сәбәпле булу, килеп чыгу; *малярия вызывается укусом малярийного комара* — малярия озынборын тешләүдән була.

**ВЫЗЫВА'ЮЩЕ** *нареч.*— ачу китерерлек итеп; *он вёл себя вызывающе* — ул үзен ачу китерерлек итеп тотты.

**ВЫЗЫВА'ЮЩИЙ** — **1.** чакырып чыгаручы, чакыручы; **2.** ачу китерә торган, ачу китергеч, ачу китерерлек; *вызывающий вид* — ачу китерерлек кыяфәт, ачу китерә торган төс.

**ВЫЗЯБА'ТЬ** *несов. обл.*— к. вызябнуть.

**ВЫ'ЗЯБНУТЬ** *сов. обл.*— өшеп бетү, өшеп һәлак булу; *посевы вызябли* — уҗымнар өшеп һәлак булган.

**ВЫ'ИГРАТЬ** *сов.*— **1.** оту; *выиграть десять тысяч рублей* — ун мең сум оту; **2.** файда итү, оту, янга калдыру; *выиграть время* — вакытны оту; **3.** өстен чыгу; җиңеп чыгу, отып чыгу, оту; *выиграть сражение* — сугышта җиңеп чыгу.

**ВЫИ'ГРЫВАТЬ** *несов.*— к. выиграть.

**ВЫИ'ГРЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— файда ителү; янга калдырылу.

**ВЫ'ИГРЫШ** *м.*—**1.** отыш; *крупный выигрыш* — зур отыш; **2.** *(то, что выиграно)* отылган, отып алынган; **3.** отып чыгу, җиңеп чыгу; *нужно добиться выигрыша* — җиңеп чыгуга ирешергә кирәк; **4.** *(выгода, польза)* файда, табыш. ◇ **Быть в выигрыше** — **1)** отышлы булу, отып чыгу; **2)** *перен.* өстен чыгу.

**ВЫ'ИГРЫШНЫЙ** —**1.** откан, отып алган; *выигрышные деньги* отып алган акча; **2.** отышлы; *выигрышный заём* — отышлы заём; **3.** *перен.* уңайлы, уңышлы, файдалы; *выигрышная роль* — уңышлы роль; *выигрышное положение* — уңайлы хәл.

**ВЫ'ИСКАТЬ** *сов.*— эзләп табу, тырышып эзләп табу.

**ВЫ'ИСКАТЬСЯ** *сов. разг.*— табылу; *выискалось много желающих отправиться в экспедицию* — экспедициягә барырга теләүчеләр күп табылды.

**ВЫИ'СКИВАТЬ** *несов.*— к. выискать.

**ВЫИ'СКИВАТЬСЯ** *несов.*— к. выискаться.

**ВЫ'ЙТИ** *сов.*— **1.** чыгып китү, чыгу; *выйти из комнаты* — бүлмәдән чыгып китү; *выйти в сад* — бакчага чыгу; **2.** *разг.* бетү; *у меня вышла вся бумага* — минем бөтен кәгазем бетте; **3.** *разг.* ... чыгу, булып чыгу; *портрет вышел хорошо* — портрет яхшы чыккан; *доклад вышел длинным* — доклад озын булып чыкты; **4.** килеп чыгу, барып чыгу; *из этого ничего не вышло* — моннан бернәрсә дә килеп (барып) чыкмады; **5.** чыгу; *он вышел из рабочей семьи* — ул

эшче семьясыннан чыккан; *выйти замуж* — кияүгә чыгу, тормышка чыгу. ◇ **Выйти из строя** — 1. *воен.* сафтан чыгу, стройдан чыгу; 2. *перен.* (*о ком*) эшли алмый башлау (авыру сәбәпле); (*о чём*) эшкә яраксыз хәлгә килү, ватылу, бозылу. **Выйти из терпения** — чыдар хәл калмау, тәкать кору. **Выйти из повиновения** — буйсынмый башлау. **Выйти из себя** — чәпчеп китү, ачулану, кызып китү. **Выйти в люди** — кеше арасына керү, адәм рәтенә керү. **Выйти в тираж** — 1) (*об облигациях*) тиражга чыгу; 2) *перен.* кулланылмый башлау, кулланудан чыгу. **Ростом не вышел** — тәбәнәк, карсак. **Рылом не вышел** *вульг.* — ямьсез. **Выйти из положения** — җаен табу. **Выйти из-под пера** — язылу.

**ВЫ'КАЗАТЬ** *сов.* — күрсәтү; *выказать храбрость* — батырлык күрсәтү.

**ВЫКА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. выказать.

**ВЫКА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — күрсәтелү.

**ВЫКА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. выкалить.

**ВЫКА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — яндырылу, яндырып хәзерләнү.

**ВЫ'КАЛИТЬ** *сов.* — яндыру, яндырып хәзерләү; *выкалить глиняный горшок* — балчык чүлмәк яндыру (яндырып хәзерләү).

**ВЫКА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. выколоть.

**ВЫКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. (*прокалываться*) төртеп тишелү, чәнчеп тишелү; 2. (*вырубаться из середины*) чокып алыну, уртасыннан ватып алыну.

**ВЫКА'ПЧИВАТЬ** *несов.* — к. выкоптить.

**ВЫКА'ПЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. ыслану, каклану, ысланып хәзерләнү (мәсәлән, казылык, колбаса); 2. (*покрываться копотью*) корым белән каплану, сөрем утыру.

**ВЫКА'ПЫВАТЬ** *несов.* — к. выкопать.

**ВЫКА'ПЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выкопаться; 2. *страд.* казылу, казып алыну.

**ВЫ'КАРАБКАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. үрмәләп чыгу, үрмәләп килеп чыгу; 2. *перен.* котылу, читенлек белән котылу, ерынып чыгу (берәр кыен эштән).

**ВЫКАРА'БКИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. выкарабкаться.

**ВЫКА'РМЛИВАТЬ** *несов.* — к. выкормить.

**ВЫКА'РМЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — ашатылу, туйдырылу, ашатып үстерелү.

**ВЫ'КАТ** *м. просторечь.* — к. выкатка II. ◇ **Глаза на выкат или навыкате** — күзләре шар кебек.

**ВЫ'КАТАТЬ** *сов.* — 1. тәгәрәтү, тәгәрәтеп алу, тәгәрәтеп тигезләү; *выкатать бельё* — кер тәгәрәтү; 2. *разг.* аунату; аунатып бетерү; *выкатать в снегу* — карда аунатып бетерү.

**ВЫ'КАТАТЬСЯ** *сов.* — 1. (*о белье*) тәгәрәтелү, тәгәрәтеп тигезләнү; 2. аунап бетү; *выкататься в снегу* — карда аунап бетү.

**ВЫ'КАТИТЬ** *сов.* — 1. тәгәрәтеп чыгару; 2. *разг.* килеп чыгу; *экипаж выкатил из-за угла* — экипаж чаттан килеп чыкты. ◇ **Выкатить глаза** *разг.* — күзләрне акайту, күзләрне чекрәйтү.

**ВЫ'КАТИТЬСЯ** *сов.* — 1. тәгәрәп китү, тәгәрәп төшү; *яблоки выкатились из корзины* — алмалар кәрзиннән тәгәрәп төштеләр; 2. *просторечь.* килеп чыгу.

**ВЫ'КАТКА** I *ж. мн.* нет — тәгәрәтү; *выкатка белья* — кер тәгәрәтү.

**ВЫ'КАТКА** II *ж. мн.* нет — 1. тәгәрәтеп чыгару; 2. *горн.* җир өстенә чыгару (казылган руданы).

**ВЫ'КАТЧИК** *м. горн.* — руда чыгарып торучы, руда ташучы.

**ВЫ'КАТЧИЦА** *ж.* — кер тәгәрәтүче.

**ВЫКА'ТЫВАТЬ** I *несов.* — к. выкатать.

**ВЫКА'ТЫВАТЬ** II *несов.* — к. выкатить.

**ВЫКА'ТЫВАТЬСЯ** I *несов.* — к. выкататься.

**ВЫКА'ТЫВАТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. выкатиться; 2. *страд.* тәгәрәтеп чыгарылу.

**ВЫ'КАЧАТЬ** *сов.* — 1. качать итеп бетерү, суыртып бетерү; *выкачать воду из подвала* — подвалдан суны качать итеп бетерү; *выкачать воздух* — һаваны суыртып бетерү; 2. *перен.* әкренләп алып бетерү, азлап-азлап алып бетерү, суырып бетерү; *империалисты пытаются выкачать из колоний всё богатство* — империалистлар колониаль илләрдән бөтен байлыкны суырып бетерергә маташалар.

**ВЫКА'ЧИВАТЬ** *несов.* — 1. качать итеп чыгару; суыртып чыгару; 2. *перен.* әкренләп суырту.

**ВЫКА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — качать итеп чыгарылу, суыртып чыгарылу.

**ВЫКА'ШИВАТЬ** *несов.* — к. выкосить.

**ВЫКА'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чабылып бетү.

**ВЫКА'ШЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. выкашлять.

**ВЫКА'ШЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. выкашляться.

**ВЫ'КАШЛЯТЬ** *сов. разг.* — йөткереп төкерү, йөткереп какыру.

**ВЫ'КАШЛЯТЬСЯ** *сов. разг.* — йөткереп чыгару.

**ВЫ'КИДАТЬ** *сов. разг.* — (тышка) ыргытып бетерү, ташлап бетерү; *выкидать вещи через окно* — әйберләрне тәрәзәдән ыргытып бетерү.

**ВЫКИ'ДЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. выкидать и выкинуть.

**ВЫКИ'ДЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. выкинуться; 2. *страд.* (тышка) ыргытып бетерелү, ташлап бетерелү; чыгарып ташлану.

**ВЫ'КИДЫШ** *м.* — 1. (*аборт*) бала төшерү; (*о животных*) колын салу, бозау салу, бәрән салу; 2. (*плод*) төшерелгән бала, җитлекми туган бала; (*о плоде животных*) җитлекми туган колын (бозау һ. б.).

**ВЫ'КИНУТЬ** *сов.* — 1. к. выбросить 1, 2, 3, 4; 2. *разг.* (*о преждевременных родах*) бала төшерү; (*у животных*) колын салу, бозау салу, бәрән салу. ◇ **Выкинуть штуку (номер, фокус)** — урынсызга берәр эш эшләп ташлау. **Выкинуть из головы** — баштан чыгару, баштан чыгарып ташлау, оныту. **Выкинуть флаг** *воен. мор.* — флаг

күтәрү. **Выкинуть лозунг** — лозунг ташлау. **Выкинуть на счетах** — счётка салу, счётка салып карау.

**ВЫ'КИНУТЬСЯ** *сов. простореч.* — ташлану.

**ВЫКИПА'ТЬ** *несов.* — 1. *(о жидкости)* кайнап бетү, кайнап кимү; 2. *обл.* эреп өскә чыгу; *от жары на доске смола начинает выкипать* — тактадагы сагыз эсседән эреп өскә чыга башлый.

**ВЫ'КИПЕТЬ** *сов.* — к. выкипать 1.

**ВЫ'КИПЯТИТЬ** *сов. разг.* — кайнатып җиткерү, тиешенчә кайнату, яхшылап кайнату; *выкипятить бельё* — кер кайнату.

**ВЫКИСА'ТЬ** *несов.* — әчү, әчеп җитү; *тесто хорошо выкисает* — камыр яхшы әчи.

**ВЫ'КИСНУТЬ** *сов.* — к. выкисать.

**ВЫ'КЛАДКА** *ж.* — 1. *только ед. (действие)* бушату; *выкладка вещей* — әйберләрне бушату; 2. *мат.* хисаплау, хисаплап чыгару; 3. *устар. (накладной узор)* өстән салынган бизәк.

**ВЫКЛА'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. выложить 1, 2, 3, 5.

**ВЫКЛА'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чыгарылу, чыгарып куелу; җәелү, каплану; салыну.

**ВЫ'КЛЕВАТЬ** *сов.* — 1. *(вырвать клювом)* чукып чыгару, чукып алу; 2. чүпләп бетерү, чүпләп ашап бетерү; *птицы выклевали весь овёс* — кошлар бөтен солыны чүпләп бетергәннәр.

**ВЫКЛЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. выклевать.

**ВЫКЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *(о птенцах)* борынлау, күренә башлау (йомырканың кабыгын ватып чыга башлау, чебеш турында); 2. *страд.* чукылу, чукып чыгарылу, чукып алыну.

**ВЫКЛЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. выклеить.

**ВЫКЛЕ'ИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. выклеиться; 2. *страд.* ябыштырып чыгылу.

**ВЫ'КЛЕИТЬ** *сов. разг.* — ябыштырып чыгу; *выклеить стены обоями* — стеналарга обой ябыштырып чыгу.

**ВЫ'КЛЕИТЬСЯ** *сов. разг.* — кубу, кубып төшү (ябыштырылган әйбер турында).

**ВЫ'КЛЕЙМИТЬ** *сов. спец.* — келәймә сугу, тамга салу, келәймә сугып чыгу, тамга салып чыгу.

**ВЫ'КЛЕПАТЬ** *сов. спец.* — 1. чүкеп алу; *выклепать звено из цепи* — чылбырның бер буынын чүкеп алу; 2. чүкеп ясау; *выклепать кастрюлю* — чүкеп кастрюля ясау.

**ВЫКЛЁПЫВАТЬ** *несов.* — к. выклепать.

**ВЫКЛЁПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чүкеп алыну; чүкеп ясалу.

**ВЫ'КЛИКАТЬ** *сов. простореч.* — кычкырып чакырып чыгару.

**ВЫКЛИКА'ТЬ** *несов.* — 1. барлау, барлап чыгу; *выкликать по списку* — исемлек буенча барлау; 2. *простореч. обл.* тәкмаклап елау.

**ВЫ'КЛИКНУТЬ** *сов.* — к. выкликать.

**ВЫ'КЛЮНУТЬ** *однокр.* — чукып алу, чукып чыгару.

**ВЫКЛЮЧА'ТЕЛЬ** *м. тех.* — выключатель (электр тогын тоташтыра яки өзә торган җайланма).

**ВЫКЛЮЧА'ТЬ** *несов* — к. выключить.

**ВЫКЛЮЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выключиться; 2. *страд. (о телефоне, электричестве)* өзелү, киселү; сүндерелү; *(о моторе)* сүндерелү, туктатылу; 3. чыгарылу, чыгарып ташлану, сызылу; *выключаться из списка* — исемлектән чыгарылу;

**ВЫКЛЮЧА'Я** *в знач. предлога* — кертмичә, чыгарып ташлап, исәпкә алмыйча.

**ВЫ'КЛЮЧИТЬ** *сов.* — 1. *тех.* өзү, кисү, сүндерү; *выключить электричество* — электрны өзү, кисү; 2. туктату; сүндерү; *выключить мотор* — моторны сүндерү, туктату; 3. *простореч.* сызу, сызып ташлау; чыгару; *выключить из списка* — исемлектән чыгару, исемлектән сызу.

**ВЫ'КЛЮЧИТЬСЯ** *сов.* — өзелү, сүнү.

**ВЫКЛЯ'НЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. выклянчить.

**ВЫКЛЯ'НЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — теләнеп (сoранып) алыну.

**ВЫ'КЛЯНЧИТЬ** *сов. разг.* — теләнеп алу.

**ВЫ'КОВАТЬ** *сов.* — 1. чүкеп ясау; *выковать подкову* — чүкеп дага ясау; 2. *перен.* үстерү, тәрбияләп үстерү, чыныктыру, тәрбияләп чыныктыру; *выковать новые кадры* — яна кадрлар тәрбияләп үстерү.

**ВЫ'КОВАТЬСЯ** *сов.* — 1. чүкеп ясалу; 2. *перен.* үсү, барлыкка килү; *в Советском Союзе выковались кадры строителей коммунизма* — Советлар Союзында коммунизм төзүче кадрлар үсте.

**ВЫКО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. выковать.

**ВЫКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выковаться; 2. *страд.* үстерелү, тәрбияләп үстерелү, барлыкка китерелү.

**ВЫКОВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. выковырять.

**ВЫКОВЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — чокып чыгарылу, казып чыгарылу; эзләп табылу.

**ВЫ'КОВЫРИТЬ** *сов. простореч.* — к. выковырять.

**ВЫ'КОВЫРЯТЬ** *сов. разг.* — 1. казып чыгару, чокып чыгару; 2. *перен.* эзләп табу, казып чыгару.

**ВЫКОЛА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. выколотить.

**ВЫКОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. сугып чыгарылу, бәреп чыгарылу, кагып чыгарылу; 2. сугып йомшартылу; 3. көчләп алыну, тарткалап-йолыккалап алыну.

**ВЫ'КОЛОСИТЬСЯ** *сов.* — башаклану, баш чыгару, баш кысу.

**ВЫ'КОЛОТИТЬ** *сов.* — 1. кагып чыгару, сугып (суккалап) чыгару, бәреп чыгару; *выколотить клин* — чөйне суккалап чыгару; 2. кагып чыгару, кагып чистарту; *выколотить ковёр* — келәмне кагып чистарту; *выколотить пыль* — тузанны кагып чыгару; 3. сугып (суккалап) йомшарту; *выколотить кожу* — күнне суккалап йомшарту; 4. *перен. разг. (получить с принуждением)* көчләп алу, тарткалап-йолык-

калап алу. ◇ **Выколотить дурь** *разг.* — кыйнап акылга утырту.

**ВЫ'КОЛОТЬ** *сов.* — 1. *(проткнуть остриём)* чәнчеп тишү; 2. *(сделать узор, прокалывая)* чәнчеп-чәнчеп бизәк ясау; 3. *(отколоть из середины)* чокып алу. ◇ **(Темно) хоть глаз выколи** *разг.* — (дөм караңгы) күзгә төртсәң дә күренми.

**ВЫ'КОЛУПАТЬ** *сов. разг.* — казып алу, чокып алу, кубарып алу.

**ВЫ'КОНОПАТИТЬ** *сов.* — мүкләп бетерү, мүкләп чыгу.

**ВЫ'КОПАТЬ** *сов.* — 1. казу, казып чыгару, казып алу, казып алып бетерү; *выкопать картофель* — бәрәңгене казып алу, казып алып бетерү; *выкопать яму* — чокыр казу; 2. казып чыгару; *выкопать камень из земли* — җирдән таш казып чыгару; 3. *перен.* табу, табып алу; казып чыгару; *откуда ты выкопал такую редкую книгу?* — кайдан табып алдың син мондый сирәк очрый торган китапны?

**ВЫ'КОПАТЬСЯ** *сов. разг.* — казып чыгу (мәсәлән, кар астыннан).

**ВЫ'КОПТИТЬ** *сов.* — 1. *(провялить в дыму)* каклау, ыслау; 2. *(покрыть копотью)* сөремләү, корымлау.

**ВЫ'КОПТИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(стать копчёным)* каклану, ыслану; 2. *(покрыться копотью)* корымлану, сөремләнү.

**ВЫ'КОРМИТЬ** *сов.* — асрап үстерү, ашатып үстерү, тәрбияләп үстерү.

**ВЫ'КОРПЕТЬ** *сов. разг.* — 1. тырышлык белән теләккә ирешү; 2. баш күтәрми эшләү; *выкорпел целый месяц в библиотеке* — китапханәдә бер ай буе баш күтәрми эшләде.

**ВЫ'КОРЧЕВАТЬ** *сов.* — 1. җир төпләү, (төп) чыгару; *выкорчевать пни* — төп чыгару; 2. *перен.* тамырын корыту, тамырыннан бетерү; *выкорчевать остатки капитализма* — капитализм калдыкларының тамырын корыту.

**ВЫКОРЧЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. выкорчевать.

**ВЫКОРЧЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. төпләрдән чистартылу, төпләрдән арчылу; 2. *перен.* тамыры корытылу, тамырыннан бетерелү.

**ВЫ'КОСИТЬ** *сов.* — чабып бетерү; чабып ташлау; *выкосить луг* — болындагы печәнне чабып бетерү. ◇ **Колхозник за день выкосил два трудодня** — колхозчы печән чабып бер көн эчендә ике хезмәт көне эшләде.

**ВЫ'КОСИТЬСЯ** *сов. обл.* — үтмәсләнү, кыршылып бетү (чалгы турында). ◇ **В соседнем колхозе уже выкосились** — күрше колхозда (печәнне) чабып бетергәннәр инде (күрше колхозда печән чабу эшләрен тәгәлләгәннәр инде).

**ВЫКРА'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. выкрасть.

**ВЫКРА'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выкрасться; 2. *страд.* урлану.

**ВЫКРА'ИВАТЬ** *несов.* — к. выкроить.

**ВЫКРА'ИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. выкроиться; 2. *страд.* киселү (кием турында).

**ВЫ'КРАСИТЬ** *сов. разг.* — буяу, буяп чыгу.

**ВЫ'КРАСИТЬСЯ** *сов. разг.* — буялу, буяуга буялу, буялып бетү.

**ВЫ'КРАСТЬ** *сов.* — урлау, урлап алу.

**ВЫ'КРАСТЬСЯ** *сов.* — качып чыгу, сиздермичә чыгып китү, таю, сызу.

**ВЫКРА'ШИВАТЬ** I *несов.* — к. выкрасить.

**ВЫКРА'ШИВАТЬ** II *несов. разг.* — к. выкрошить.

**ВЫКРА'ШИВАТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. выкраситься; 2. *страд.* буялу.

**ВЫКРА'ШИВАТЬСЯ** II *несов.* — валчыклану, эче коелып бетү, эче вакланып бетү.

**ВЫ'КРИК** *м.* — кычкыру, кычкырган тавыш.

**ВЫКРИ'КИВАТЬ** *несов. разг.* — к. выкрикнуть.

**ВЫКРИ'КИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. выкричаться; 2. *страд.* кычкырып әйтелү; кычкырып чакырылу.

**ВЫ'КРИКНУТЬ** *сов. разг.* — 1. кычкырып әйтү; 2. кычкыру, кычкырып чакыру; *выкрикнули пятый номер* — бишенче номерны кычкырдылар.

**ВЫ'КРИСТАЛЛИЗОВАТЬСЯ** *сов.* — 1. *хим.* кристаллашу, кристаллашып бетү, кристаллашып житү, кристалл булып оешу, кристаллга әверелү; 2. *перен.* оешу, формалашу, барлыкка килү; *выкристаллизовались новые формы быта* — көнкүрешнең яңа формалары барлыкка килде.

**ВЫКРИСТАЛЛИЗО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. выкристаллизоваться.

**ВЫ'КРИЧАТЬСЯ** *сов.* — кычкырып тую, туйганчы кычкыру, кычкыра-кычкыра арып бетү.

**ВЫ'КРОИТЬ** *сов.* — 1. кисү, кием кисү; *выкроить брюки* — чалбар кисү; 2. *перен. разг. (сэкономить)* янга калдыру, арттырып алып калу; табу; *выкроить время* — вакыт табу.

**ВЫ'КРОИТЬСЯ** *сов. разг.* — чыгу, җитү; *из этого куска материала еле выкроились брюки* — бу материал кисәгеннән чакчак кына бер чалбар чыкты.

**ВЫ'КРОЙКА** *ж.* — өлге.

**ВЫ'КРОМСАТЬ** *сов. разг.* — белер-белмәс кисеп алу.

**ВЫ'КРОШИТЬ** *сов. разг.* — валчыкландырып коеп бетерү.

**ВЫ'КРОШИТЬСЯ** *сов.* — кителү, кителеп бетү; *зубы выкрошились* — тешләрем кителеп бетте.

**ВЫКРУТА'СЫ** *ед.* нет, *разг.* — 1. боргалану, боргалану-сыргалану, кылану; 2. *перен.* артык бизәкләп сөйләү; *он говорил с выкрутасами* — ул артык бизәкләп сөйләде.

**ВЫ'КРУТИТЬ** *сов.* — 1. *спец. (свить)* ишеп ясау, бөтереп ясау; 2. *(вывинтить)* борып чыгару, борып алу; *выкрутить лампочку из патрона* — лампаны патроннан борып алу; 3. *(выжать скрутив)* борып сыгу, сыгу; 4. борып каймыктыру;

*мальчику выкрутили руку* — малайның кулын борып каймыктырганнар.

**ВЫ'КРУТИТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* борылып чыгу; 2. *перен. разг.* котылу, котылып чыгу.

**ВЫКРУ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. выкрутить.

**ВЫКРУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. выкрутиться; 2. *страд.* борып чыгарылу, борып алыну.

**ВЫКРЫВА'ТЬ** *несов. спец.* — к. выкрыть.

**ВЫКРЫВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — җәеп чыгылу, каплап чыгылу.

**ВЫ'КРЫТЬ** *сов. спец.* — җәеп чыгу; түшәп чыгу; *выкрыть пол линолеумом* — идәнгә линолеум җәеп чыгу.

**ВЫ'КУКОВАТЬ** *сов. разг.* — хәбәр бирү (халык ышануы буенча, күке кычкырып кешенең ничә ел яшәячәге турында хәбәр бирә имеш); *кукушка выкуковала ему ещё пять лет жизни* — күке аның тагы биш ел яшәячәге турында хәбәр бирде.

**ВЫ'КУП** *м.* — 1. *только ед. (действие)* йолып алу; 2. *(плата)* йолым, түләү; йолым акчасы.

**ВЫ'КУПАТЬ** *сов.* — коендыру, юындыру; *выкупать ребёнка* — баланы коендыру.

**ВЫКУПА'ТЬ** *несов.* — к. выкупить.

**ВЫ'КУПАТЬСЯ** *сов.* — коену, юыну, су керү, су коену.

**ВЫКУПА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. йолып алыну, (түләп) азат ителү; 2. *(о вещи)* түләп алыну.

**ВЫ'КУПИТЬ** *сов.* — 1. йолып алу, түләп азат итү; *выкупить пленных* — пленныйларны йолып алу; 2. түләп алу; *выкупить вещи из-под залога* — әйберләрне закладтан түләп алу.

**ВЫ'КУПИТЬСЯ** *сов.* — к. выкупа́ться.

**ВЫКУПНО'Й** — түләп алу ...-ы; *выкупное право* — түләп алу хокукы.

**ВЫ'КУПЩИК** *м.* — түләп алучы.

**ВЫКУ'РИВАТЬ** *несов.* — к. выкурить.

**ВЫКУ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выкуриться; 2. *страд. (о табаке)* тартып бетерелү; *(дымом)* төтәсләп чыгарылу; *(о спирте, смоле)* куылу, куып ясалу.

**ВЫ'КУРИТЬ** *сов.* — 1. *(о табаке, папиросе)* тартып бетерү; 2. төтәсләп чыгару; *выкурить пчёл из улья* — кортларны умартадан төтәсләп чыгару; 3. *перен. разг.* куып чыгару, чыгарып җибәрү (озату); *еле выкурили непрошенных гостей* — чакырылмый килгән кунакларны көчкә генә чыгарып җибәрдек (озаттык); 4. *(о спирте, смоле)* куу, куып ясау.

**ВЫ'КУРИТЬСЯ** *сов.* — 1. *(о табаке)* тартылып бетү; 2. *(о спирте, дёгте и т. п.)* куылу, куып алыну.

**ВЫ'КУСАТЬ** *сов. простореч.* — тешләптешләп алу.

**ВЫ'КУСИТЬ** *сов.* — кимереп бетерү, кимереп ашап бетерү, тешләп алып бетерү.

**ВЫКУ'СЫВАТЬ** *несов.* — к. выкусать.

**ВЫКУ'СЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кимереп бетерелү, кимереп ашап бетерелү, тешләп алып бетерелү.

**ВЫ'КУШАТЬ** *сов. устар.* — эчү, эчеп алу; *выкушайте еще чашечку чайку* — тагы бер генә чынаяк (чәй) эчегез инде!

**ВЫЛА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. выловить.

**ВЫЛА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — тотылу, тотып бетерелү.

**ВЫ'ЛАЗ** *м. простореч.* — чыгып йөрерлек тишек (мәсәлән, стенада).

**ВЫ'ЛАЗИТЬ** *сов. разг.* — үрмәләп (шуышып) йөреп чыгу; *ребёнок вы́лазил все углы* — бала үрмәләп (шуышып) бөтен җирне йөреп чыкты.

**ВЫЛА'ЗИТЬ** *несов., обл. простореч.* — чыгу; *вылáзьте живей!* — тизрәк чыгыгыз!

**ВЫ'ЛАЗКА** *ж.* — 1. *воен.* вылазка, чыгыш, һөҗүм (камалуда ятучыларның камап торучыларга каршы чыгышы); 2. *перен.* каршы чыгу, һөҗүм; *вылазка классового врага* — сыйныфый дошманның һөҗүме; 3. *спорт.* вылазка.

**ВЫ'ЛАКАТЬ** *сов.* — 1. *(о кошке и собаке)* эчеп бетерү, ялап бетерү; 2. *простореч. презр. (выпить до конца)* эчеп бетерү, чөмереп бетерү.

**ВЫЛА'МЫВАТЬ** *несов.* — к. выломать.

**ВЫЛА'МЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. ватып алыну, ватып чыгарылу; 2. сындырып алыну.

**ВЫЛА'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. вылощить.

**ВЫЛА'ЩИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. вылощиться; 2. *страд.* ялтыратылу, шомартылу.

**ВЫ'ЛЕЖАТЬ** *сов. разг.* — яту; *больной вылежал в постели целую неделю* — авыру атна буена түшәктә ятты.

**ВЫ'ЛЕЖАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. хәл кергәнче яту; 2. озак ятып элекке хәленә кайту (таушалган тукыма яки кәгазь турында әйтелә); 3. өлгереп житү; *помидоры на полке вылежались* — помидорлар шүрлектә ятып өлгереп җиттеләр; 4. *(выдохнуться)* озак ятып тәме бетү, айну.

**ВЫЛЁЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. вылежать.

**ВЫЛЁЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. вылежаться.

**ВЫЛЕЗА'ТЬ** *несов.* — 1. чыгу, үрмәләп чыгу, шуышып чыгу, мүкәләп чыгу; *вылезать из ямы* — чокырдан чыгу; 2. *разг. (выходить)* чыгып килү; төшеп килү; *старик с трудом вылезал из вагона* — карт көчкә-көчкә вагоннан чыгып килә иде; 3. коелу; *после тифа вылезают волосы* — тифтән соң чәч коела; 4. *разг. неодобр.* чыгу; *вылезать с глупыми предложениями* — мәгънәсез тәкъдимнәр белән чыгу. ◇ **Вылезать из кожи** — бөтен көчне кую, жаны чыкканчы тырышу.

**ВЫ'ЛЕЗТИ и ВЫ'ЛЕЗТЬ** *сов.* — к. вылезать 1, 3, 4 и выла́зить.

**ВЫ'ЛЕПИТЬ** *сов.* — әвәләп ясау, сылап ясау (берәр сурәтне). ◇ **Память вылепила милые черты лица матери** — хәтерем әниемнең сөйкемле йөзен күз алдыма китереп бастырды.

**ВЫ'ЛЕПИТЬСЯ** *сов.* — әвәләп ясалу, сылап ясалу.

**ВЫЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. вылепить.

**ВЫЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. вылепиться.

**ВЫ'ЛЕТ** *м.* — 1. *(действие)* очып чыгу; *вылет птиц* — кошларның очып чыгуы; 2. очып китү вакыты; *вылет эскадрильи назначен на 5 часов*—эскадрильяның очып китү вакыты сәгать 5 кә билгеләнгән; 3. очыш; *лётчик сделал пять вылетов* — очучы биш очыш ясады. ◇ **На вылет** (или **навылет**) — үтәли, үтәдән-үтә.

**ВЫЛЕТА'ТЬ** *несов.* — к. вылететь.

**ВЫ'ЛЕТЕТЬ** *сов.*—1. очып чыгу, очып килеп чыгу; очып чыгып китү; *птица вылетела из клетки* — кош читлектән очып чыгып китте; 2. чабып килеп чыгу, атылып килеп чыгу, йөгереп килеп чыгу; *кто-то вылетел из-за угла* — кемдер чаттан атылып килеп чыкты; 3. төшү, төшеп китү; *листок вылетел из книги* — китапның бите төште; 4. *разг. фам.* куылу; *вылететь со службы* — хезмәттән куылу. ◇ **Вылететь из саней** — чанадан егылып төшү. **Хмель вылетел** — кинәт айнып китте. **Вылететь из головы** — баштан чыгу, истән чыгу, хәтердән чыгу, онытылу. **Вылететь в трубу** — бөлү, банкрот булу.

**ВЫЛЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. вылечить.

**ВЫЛЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. вылечиться; 2. *страд.* сәламәтләндерелү, савыктырылу.

**ВЫ'ЛЕЧИТЬ** *сов.* — 1. терелтү, дәвалап терелтү, савыктыру, сәламәтләндерү; 2. *перен.* ташлату, биздерү.

**ВЫ'ЛЕЧИТЬСЯ** *сов.* — 1. терелү, дәваланып терелү, савыгу, сәламәтләнү; 2. *перен.* бизү, тыелу, тукталу (берәр гадәттән).

**ВЫЛИВА'ТЬ** *несов.* — к. вылить.

**ВЫЛИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. вылиться; 2. *страд.* түгелү, агызылу.

**ВЫ'ЛИЗАТЬ** *сов. разг.* — 1. ялап чистарту, ялап тазарту, ялап алу; *вылизать тарелку* — тәлинкәне ялап чистарту; 2. *(облизать всю поверхность)* ялап бетерү, ялап чыгу.

**ВЫ'ЛИЗАТЬСЯ** *сов. разг.* — ялanып чистарыну.

**ВЫЛИ'ЗЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. вылизать.

**ВЫЛИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. вылизаться; 2. *страд.* ялап чистартылу, ялап тазартылу; ялап алыну, ялап бетерелү.

**ВЫ'ЛИНЯТЬ** *сов. разг.* — 1. *(выцвести)* уңу, төс китү, уңып бетү, төсе китеп бетү; 2. *(о лошади и корове)* ябага кою; *(об овцах)* йон коюь; *(о козе)* мамык коюь; *(о птицах)* каурый коюь; *(о зайцах)* төс алмаштыру.

**ВЫ'ЛИТЫЙ** — 1. түгелгән, агызылган; 2. *(из металла)* коелган, коеп ясалган; 3. *(похожий)* нәкъ үзе, охшаган, коеп куйгандай, суеп каплагандай, суйган да куйган, суйган да каплаган.

**ВЫ'ЛИТЬ** *сов.* — 1. түгү, агызу; *вылить воду из бочки* — мичкәдән су агызу; 2. кою; *вылить свечу из воска* — балавыздан шәм кою. ◇ **Вылить хомяков** *обл.*— әрләннәрне (оядан) су белән куып чыгару.

**ВЫ'ЛИТЬСЯ** *сов.* — 1. агу, түгелү; *вода вылилась из бутылки* — су шешәдән түгелгән (аккан); 2. *перен.* килеп чыгу, кайнап чыгу (берәр тәэсир нәтиҗәсендә); *песня вылилась из сердца* — җыр йөрәктән кайнап чыкты; 3. *перен.* әйләнү, әверелү, төс алу, төскә керү, форма алу; *протест рабочих против капиталистических порядков вылился в мощную демонстрацию* — эшчеләрнең капиталистик тәртипләргә каршы протесты көчле демонстрациягә әйләнде.

**ВЫ'ЛОВ** *м. мн.* нет — 1. *(действие)* аулау, балык аулау, балык тоту; *план вылова* — балык тоту планы; 2. тотылган балыкның күләме; *суточный вылов—сто центнеров* — тәүлек эчендә тотылган балыкның күләме йөз центнер.

**ВЫ'ЛОВИТЬ** *сов.* — 1. тотып алу; *выловить бревно из воды* — судан бүрәнәне тотып алу; 2. *(переловить всё)* тотып бетерү, тотып алып бетерү.

**ВЫ'ЛОЖИТЬ** *сов.* — 1. чыгарып кую, чыгарып салу; *выложить товар на прилавок* — товарны прилавкага чыгарып салу; 2. *перен. разг.* — бөтенесен сөйләп бирү, әйтеп бирү; *что знал, всё выложил* — бар белгәнен сөйләп бирде; 3. каплап чыгу, түшәп чыгу, җәеп чыгу; *выложить мостовую булыжником* — урамга таш җәеп чыгу; 4. *портн.* тотып чыгу, тегеп чыгу; *выложить платье белым кружевом* — күлмәккә ак челтәр тотып (тегеп) чыгу; 5. салу; *выложить стену* — стена салу.

**ВЫ'ЛОКАТЬ** *сов.* — к. вылакать.

**ВЫ'ЛОМ** *м.* — 1. *только ед.* *(действие)* к. выломать; 2. *(пролом)* ватылган урын, тишек.

**ВЫ'ЛОМАТЬ** *сов.* — 1. ватып алу, ватып чыгару; 2. *(ломая добыть)* сындырып алу; 3. *простореч.* каймыктыру; *выломать руку* — кулны каймыктыру.

**ВЫ'ЛОМИТЬ** *сов. простореч.* — к. выломать.

**ВЫ'ЛОЩИТЬ** *сов.* — шомарту, ялтырату.

**ВЫ'ЛОЩИТЬСЯ** *сов. разг.* — шомару, ялтырау.

**ВЫ'ЛУДИТЬ** *сов.* — лудить итү, кургаш йөгертү; *вылудить самовар* — самоварның эченә кургаш йөгертү.

**ВЫЛУ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. вылудить.

**ВЫЛУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — лудить ителү, кургаш йөгертелү.

**ВЫ'ЛУПИТЬ** *сов. простореч.* — кабыгын әрчү. ◇ **Вылупить глаза** *разг.* — күзне акайту, күзне чекрәйтү.

**ВЫ'ЛУПИТЬСЯ** *сов.* — чыгу; *утята вылупились* — үрдәк бәбкәләре чыкты.

**ВЫЛУПЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — к. вылупить.

**ВЫЛУПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. вылупиться; 2. *страд.* әрчелү, кабыгы әрчелү.

**ВЫЛУ'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. вылущить.

**ВЫЛУ'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — әрчелү, тазартылу.

**ВЫ'ЛУЩИТЬ** *сов.* — әрчү, тазарту; *вылущить горох*—борчак әрчү, борчак тазарту.

**ВЫ'МАЗАТЬ** *сов.* — 1. *(обмазать)* сөртеп чыгу, сылап чыгу; 2. *разг. (испачкать)* буяп бетерү, пычратып бетерү; 3. буяп бетерү, тотып бетерү; *вымазать три банки белил* — өч банка ак буяу тотып бетерү.

**ВЫ'МАЗАТЬСЯ** *сов. разг.* — буялып бетү, пычранып бетү.

**ВЫМА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. вымазать.

**ВЫМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. *разг.* к. вымазаться; 2. *страд.* сөртеп чыгылу, сылап чыгылу; буяп бетерелү, пычратып бетерелү; тотып бетерелү (буяуга).

**ВЫ'МАЛЕВАТЬ** *сов. простореч.* — 1. буяп ташлау, начар итеп буяу, начар итеп рәсем ясау; 2. тотып бетерү, буяп бетерү; *вымалевать целую банку краски* — бер банка буяу тотып бетерү.

**ВЫМАЛЁВЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. вымалевать.

**ВЫМАЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — 1. начар итеп ясалу (рәсем), начар итеп буялу; 2. *(о краске)* тотылып бетү.

**ВЫМА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. вымолить.

**ВЫМА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — ялынып сорап алыну, ялынып-ялварып алыну.

**ВЫМА'ЛЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. вымолоть.

**ВЫМА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. вымолоться.

**ВЫМА'НИВАТЬ** *несов.* — к. выманить.

**ВЫМА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. хәйлә белән алыну, хәйләләп алыну, алдалап алыну; 2. алдалап чыгарылу, кызыктырып чыгарылу.

**ВЫ'МАНИТЬ** *сов.* — 1. *(получить хитростью)* хәйлә белән алу, хәйләләп алу, алдалап алу; 2. *(хитростью заставить выйти)* алдап чыгару, кызыктырып чыгару. ◇ **Калачом не выманишь** — бернәрсә белән дә алдап чыгара алмассың.

**ВЫ'МАРАТЬ** *сов.* — 1. *(запачкать)* пычратып бетерү, буяп бетерү; 2. сызып ташлау; *вымарал две строчки* — ике юлны сызып ташладым.

**ВЫ'МАРАТЬСЯ** *сов. простореч.* — пычранып бетү, буялып бетү.

**ВЫМА'РИВАТЬ** *несов.* — к. выморить.

**ВЫМА'РИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кырып бетерелү, үтереп бетерелү.

**ВЫМА'РЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. вымарать.

**ВЫМА'РЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. вымараться; 2. *страд.* пычратып бетерелү, буяп бетерелү; сызылу, сызып ташлану.

**ВЫМА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. вымотать.

**ВЫМА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. вымотаться; 2. *страд.* уралу, чорналу, сарылу; тотып бетерелү (уралган җеп турында).

**ВЫ'МАХАТЬ** *сов.* — 1. *(приучить лошадь к рыси)* юыртырга өйрәтү; 2. *разг.* куып чыгару, куып чыгарып бетерү; *вымахать комаров* — озынборыннарны куып чыгару.

**ВЫМА'ХИВАТЬ** *несов.* — к. вымахать.

**ВЫ'МАХНУТЬ** *простореч.* — 1. селкеп чыгару; 2. *(быстро выскочить)* чәчрәп чыгып китү, атылып чыгып китү; *мышь мигом вымахнула из мышеловки* — тычкан тәбедән күз ачып йомганчы атылып чыгып китте.

**ВЫМА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. вымочить.

**ВЫМА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. вымочиться; 2. *страд.* чылатылу, җебетелү, юешләтелү.

**ВЫМА'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. вымостить.

**ВЫМА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. вымоститься.

**ВЫ'МЕЖЕВАТЬ** *сов. спец.* — межалап алу (җир участогының бер өлешен).

**ВЫ'МЕЖЕВАТЬСЯ** *сов. спец.* — межалап алыну (җир участогының бер өлеше).

**ВЫМЕЖО'ВЫВАТЬ** *несов. спец.* — к. вымежевать.

**ВЫМЕЖО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. спец.* — к. вымежеваться.

**ВЫ'МЕЛИТЬ** *сов. разг.* — 1. акбур белән агарту, акшарлау; 2. *(выпачкать мелом)* акбурга пычратып бетерү.

**ВЫ'МЕЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — акбурга буялу, акбурга пычрану.

**ВЫМЕ'НИВАТЬ** *несов.* — к. выменять.

**ВЫМЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — алыштырылу, алыштырып алыну.

**ВЫ'МЕНИТЬ** *сов. разг.* — к. выменять.

**ВЫ'МЕНЯТЬ** *сов.* — алышу, алышып алу.

**ВЫ'МЕРЕТЬ** *сов.* — 1. *(поголовно исчезнуть вследствие смерти)* үлеп бетү, кырылып бетү; 2. *перен.* *(обезлюдеть, опустеть)* бушап калу, кешесез калу.

**ВЫМЕРЗА'ТЬ** *несов.* — 1. өшеп һәлак булу; *фруктовые деревья зимой часто вымерзают* — җимеш агачлары кышын өшеп еш кына һәлак булалар; 2. кату, туну, бозга әйләнү.

**ВЫ'МЕРЗНУТЬ** *сов.* — к. вымерзать.

**ВЫМЕ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. вымерять.

**ВЫМЕ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. вымеряться.

**ВЫ'МЕРИТЬ** *сов.* — үлчәү, үлчәп чыгу; *вымерить площадь комнаты* — бүлмәнең мәйданын үлчәп чыгу. ◇ **Вымерить взглядом** — башыннан аягына кадәр күз йөртеп чыгу.

**ВЫ'МЕРЯТЬ** *сов.* — к. вымерить.

**ВЫМЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. вымерить.

**ВЫМЕРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — үлчәнелү, үлчәп чыгылу.

**ВЫ'МЕСИТЬ** *сов. разг.* — басу, изү; *вымесить тесто* — камыр басу; *вымесить глину* — балчык изү.

**ВЫ'МЕСИТЬСЯ** *сов. разг.* — басылып җитү, изелеп җитү (камыр яки балчык турында).

**ВЫ'МЕСТИ** *сов.* — к. выметать.

**ВЫ'МЕСТИСЬ** *сов.* — к. выметаться.

**ВЫ'МЕСТИТЬ** *сов. устар.* — үч алу, үч кайтару, ачу алу, кару кайтару.

**ВЫ'МЕТАТЬ** *сов. портн.* — чалу, чалып тегү; *выметать петли* — элмәк чалу.

**ВЫМЕТА'ТЬ** *несов.* — 1. себереп чыгару, себереп ташлау; *выметать сор* — чүпне

себереп чыгару; 2. себерү, себереп чыгу, себереп чистарту; *выметать комнату* — бүлмәне себерү; 3. *перен. простореч. вульг. (выгонять)* куып чыгару, сөреп чыгару.

**ВЫМЕТА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* себерелү, себереп чыгарылу, себереп ташлану; 2. *перен. простореч. вульг. (уходить)* чыгып китү, табан ялтырату, үкчә күтәрү.

**ВЫ'МЕТИТЬ** *сов. простореч.* — билге куеп чыгу, тамга салып чыгу; билгеләп (тамгалап) чыгу.

**ВЫМЁТЫВАТЬ** *несов. портн.* — к. выметать.

**ВЫМЕЧА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. выметить.

**ВЫМЕЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — билге куелу, билге салыну, тамга салыну, билге (тамга) куеп чыгылу.

**ВЫ'МЕШАТЬ** *сов.* — болгатып куерту.

**ВЫМЕ'ШИВАТЬ** I *несов. разг.* — к. вымесить.

**ВЫМЕ'ШИВАТЬ** II *несов.* — к. вымешать.

**ВЫМЕ'ШИВАТЬСЯ** I *несов. разг.* — басылу, изелү (мәсәлән, камыр).

**ВЫМЕ'ШИВАТЬСЯ** II *несов.* — болгатып куертылу.

**ВЫМЕЩА'ТЬ** *несов.* — к. выместить.

**ВЫМЕЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — үч алыну, үч кайтарылу, ачу алыну, кару кайтарылу.

**ВЫМИНА'ТЬ** *несов.* — 1. *разг.* изү, изеп йомшарту; *выминать глину* — балчык изү; 2. *обл.* таптап бетерү, изеп бетерү; *лошади выминают траву во дворе* — атлар ишек алдындагы чирәмне таптап бетерәләр.

**ВЫМИНА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — 1. изелү, изеп йомшартылу; 2. таптап бетерелү, изеп бетерелү.

**ВЫМИРА'ТЬ** *несов.* — к. вымереть.

**ВЫ'МИСТЫЙ** *обл.*: **вымистая корова** — зур җиленле сыер.

**ВЫМОГА'ТЕЛЬ** *м.*, **ВЫМОГА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — куркытып алучы, көчләп алучы.

**ВЫМОГА'ТЕЛЬСКИЙ** — куркытып алу... -ы, көчләп алу ... -ы; *вымогательские действия* — куркытып алу эшләре.

**ВЫМОГА'ТЕЛЬСТВО** *ср. презр.* — к. вымогать.

**ВЫМОГА'ТЬ** *несов. презр.* — көчләп алу, куркытып алу.

**ВЫМОГА'ТЬСЯ** *несов. страд. презр.* — көчләп алыну, куркытып алыну.

**ВЫ'МОИНА** *ж. обл.* — ерганак.

**ВЫМОКА'ТЬ** *несов.* — к. вымокнуть.

**ВЫ'МОКНУТЬ** *сов.* — 1. җебеп җитү, чыланып җитү (йомшау); *лён вымок* — житен чыланып җиткән; 2. тозы чыгып бетү; *солонина вымокла* — тозлаган итнең тозы чыгып беткән; 3. черү, череп бетү, бурсу; *посевы вымокли от постоянных дождей* — өзлексез яңгырлардан уҗымнар череп бетте; 4. *(промокнуть)* манма су булу, бик нык чылану. ◇ **Вымокнуть до нитки** — энәсеннән җебенә кадәр чылану.

**ВЫМОЛА'ЧИВАТЬ** *несов. с-х.* — к. вымолотить.

**ВЫМОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.* — сугылу, сугып бетерелү.

**ВЫ'МОЛВИТЬ** *сов.* — 1. әйтү, сүз кушу, эндәшү; *за весь вечер он слова не вымолвил* — бөтен кич буена ул бер сүз дә эндәшмәде; 2. *устар. (выпросить)* сорап алу.

**ВЫ'МОЛИТЬ** *сов. разг.* — ялынып сорап алу, үтенеп сорап алу; ялварып сорап алу.

**ВЫ'МОЛОТ** *м. обл. с.-х.* — төшем, ашлык чыгышы.

**ВЫ'МОЛОТИТЬ** *сов.* — 1. сугып бетерү (ашлыкны); 2. *(заработать молотьбой)* ашлык сугып акча яки хезмәт көне эшләү.

**ВЫ'МОЛОТКИ** *ед. нет, обл.* — ындыр чүбе, ындыр төбе, очык (ашлык сукканнан соң ындыр табагында калган чүп-чар).

**ВЫ'МОЛОТЬ** *сов. разг.* — тарттыру; *вымолоть два мешка ржи* — ике капчык арыш тарттыру.

**ВЫ'МОЛОТЬСЯ** *сов.* — *(о жерновах)* тузу, шомарып бетү.

**ВЫМОРА'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. выморозить.

**ВЫМОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. вымрозиться; 2. *страд. (о помещении)* суытылу; *(о белье)* туңнан ашатылу; *(о насекомых)* туңдырып үтерелү, катырып үтерелү.

**ВЫ'МОРИТЬ** *сов.* — 1. *(голодом)* ачыктырып үтереп бетерү; 2. *(отравой)* агулап кырып бетерү.

**ВЫ'МОРОЗИТЬ** *сов. разг.* — 1. суыту; *выморозить комнаты* — бүлмәләрне суыту; 2. туңнан ашату; *выморозить бельё* — керне туңнан ашату; 3. катырып үтерү, катырып бетерү; *выморозить тараканов* — тараканнарны катырып бетерү.

**ВЫ'МОРОЗИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. суыну; 2. туң ашау; *бельё выморозилось* — керне туң ашаган.

**ВЫ'МОРОЧНЫЙ** *юр.* — вариссыз калган, иясез калган; *выморочное имущество* — вариссыз калган мөлкәт (иясе үлгәч, аның артында калыр кешесе булмау сәбәпле хөкүмәт кулына күчкән мөлкәт).

**ВЫ'МОСТИТЬ** *сов.* — җәеп чыгу, түшәп чыгу; *вымостить дорогу булыжником* — юлга чуер таш җәеп чыгу.

**ВЫ'МОСТИТЬСЯ** *сов.* — түшәлү, җәелү (юлга таш һ. б.).

**ВЫ'МОТАТЬ** *сов. разг.* — 1. сару, урау, чорнау; *вымотать два мотка ниток* — ике басма җеп сару; 2. тотып бетерү; *вымотать целый моток* — бер басма җеп тотып бетерү; 3. *перен. (изнурить)* алҗытып бетерү, интектереп бетерү, йончытып бетерү. ◇ **Вымотать душу** — үзәккә үтү, теңкәгә тию.

**ВЫ'МОТАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. тотылып бетү, эшкә китеп бетү; *два клубка вымотались* — ике йомгак тотылып бетте; 2. чыгу, булу; *из всей шерсти вымотались три клубка* — бөтен йоннан өч йомгак җеп чыкты; 3. *фам.* хәлдән таю, интегеп бетү, алҗып бетү, теңкә кору.

**ВЫ'МОЧИТЬ** *сов. разг.* — 1. *(промочить)* юешләтү, чылату, юешләтеп бетерү, чыла-

тып бетерү; 2. жебетү, чылату; *вымочить лён* — житен чылату; 3. суга салып тозын чыгару; *вымочить селёдку* — суга салып селёдканың тозын чыгару.

**ВЫ'МОЧИТЬСЯ** *сов. простореч.*— чылану, чыланып бетү.

**ВЫ'МПЕЛ** *м.*— вымпел (сугыш кораблендә озын тар флаг).

**ВЫМУ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. вымучить.

**ВЫМУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— мәҗбүр ителү.

**ВЫ'МУЧИТЬ** *сов.*— 1. мәҗбүр итү; 2. көчәнеп ... -у; *вымучить мысль* — көчәнеп бер фикер әйтү; *вымучить стихи* — көчәнеп шигырьләр язу.

**ВЫ'МУШТРОВАТЬ** *сов. разг.*— муштра белән өйрәтү, таяк дисциплинасы белән өйрәтү.

**ВЫМЫВА'ТЬ** *несов.*— к. вымыть.

**ВЫМЫВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. вымыться; 2. *страд.* юылу; ашалу.

**ВЫМЫ'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. вымылить.

**ВЫМЫ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. вымылиться; 2. *страд.* юуга тотылып бетү (сабын турында).

**ВЫ'МЫЛИТЬ** *сов. разг.*— тотып бетерү, юып бетерү; *вымылить целый кусок мыла* — бер кисәк сабын тотып бетерү.

**ВЫ'МЫЛИТЬСЯ** *сов. разг.*— тотылып бетү, юуга китеп бетү, юуга тотылып бетү (сабын турында).

**ВЫ'МЫСЕЛ** *м.*— 1. *книж. поэт.* хыял, фантазия; 2. уйдырма, ялган.

**ВЫ'МЫСЛИТЬ** *сов. устар.*— к. вымышлять.

**ВЫ'МЫТЬ** *сов.*— 1. юу, юып чистарту; юындыру; 2. *обл.* ашау, юып алып китү; *водой вымыло берег* — ярны су ашаган.

**ВЫ'МЫТЬСЯ** *сов.*— юыну.

**ВЫМЫШЛЯ'ТЬ** *несов. устар.*— уйлап чыгару; уйдырма кору.

**ВЫМЫШЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. устар.*— уйлап чыгарылу; уйдырма корылу.

**ВЫ'МЯ** *ср.*— җилен.

**ВЫНА'ШИВАТЬ** *несов.*— 1. күтәрү (баланы карында чакта); 2. *перен.* башта йөртү, күңелдә йөртү, уйлап йөрү (берәр уйны).

**ВЫНА'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд. перен.*— башта йөртелү, күңелдә йөртелү (берәр уй, фикер, план турында).

**ВЫ'НЕСТИ** *сов.*— 1. чыгару, алып чыгу; китереп чыгару, чыгарып ташлау; *вынести вещи на улицу* — әйберләрне урамга чыгару; *волной вынесло лодку на берег* — дулкын көймәне ярга китереп чыгарды (чыгарып ташлады); 2. *перен.* кую, чыгару; *вынести вопрос на общее собрание* — мәсьәләне гомуми җыелышка кую; 3. *перен.* кабул итү, чыгару; *вынести решение* — карар чыгару, карар кабул итү; 4. *перен.* килү, алып чыгу, алу; *вынести убеждение* — фикергә килү; *вынести впечатление* — тәэсир алу, тәэсир алып чыгу; 5. чыдау; түзү; *вынести сильную боль* — каты авыртуга чыдау. ◇ **Вынести на поля рукописи** — кульъязманың читенә чыгарып язу. **Вынести на своих плечах** — бер үзе башкарып чыгу.

**ВЫ'НЕСТИСЬ** *сов. разг.*— 1. к. выноситься; 2. (*стремительно выехать, выбежать*) атылып чабып чыгу, атылып йөгереп чыгу.

**ВЫ'НИЗАТЬ** *сов. устар.*— бизәп чыгу (энҗе, сәйлән һ. б. белән).

**ВЫНИМА'ТЬ** *несов.*— к. вынуть.

**ВЫНИМА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. вынуться; 2. алыну; *этот ящик стола не вынимается* — өстәлнең бу ящигы алынмый.

**ВЫ'НОС** *м. мн.* нет — 1. алга ташлау; *вынос левой ноги вперёд* — сул аякны алга ташлау; 2. алып чыгу; күтәреп чыгу; *вынос тела покойника из квартиры* — мәетне квартирадан алып чыгу.

**ВЫ'НОСИТЬ** *сов.*— 1. *разг.* күтәрү (карындагы баланы); 2. *перен.* уйлап тудыру; *выносить идею* — идея уйлап тудыру.

**ВЫНОСИ'ТЬ** *несов.*— 1. к. вынести. ◇ **Не выносить** *(кого-л.)* — күрәлмау; *он не выносит этого человека* — ул бу кешене күрәлмый (дошман күрә). **Не выносить сор из избы** — йортындагыны кешегә чыгармау (ике арада булганны кешегә сөйләмәү, сүз йөртмәү, сүз таратмау).

**ВЫНОСИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. чыгарылу; 2. куелу, уртага куелу, чыгарылу; *вопрос выносится на обсуждение* — мәсьәлә тикшерүгә куела; 3. *разг.* ташыну; *когда загорелся дом, жители стали спешно выноситься* — өй яна башлагач, анда торучылар ашыга-ашыга ташына башладылар.

**ВЫ'НОСКА** *ж. мн.* нет — 1. *(действие)* чыгару, алып чыгу; 2. искәрмә, аңлатма (сызык астына төшереп язылган искәрмә); *выноска под строкой* — сызык астындагы искәрмә.

**ВЫНО'СЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — чыдамлылык, түземлелек, чыдамлы булу, түземле булу.

**ВЫНО'СЛИВЫЙ** — чыдам, чыдамлы, түзем, түземле, түзүчән.

**ВЫНОСНО'Й** — чыгарып язу ... -ы; искәрмәләр ... -ы; *выносная графа* — искәрмәләр графасы. ◇ **Выносные лошади** — мичәү атлары; очка җигелгән атлар.

**ВЫ'НУДИТЬ** *сов.*— 1. мәҗбүр итү; *вынудить противника отступить* — дошманны чигенергә мәҗбүр итү; 2. мәҗбүр итеп алу; *вынудить согласие* — мәҗбүр итеп ризалыгын алу.

**ВЫНУЖДА'ТЬ** *несов.*— к. вынудить.

**ВЫНУЖДА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— мәҗбүр ителү.

**ВЫ'НУТЬ** *сов.*— алу, чыгару; *вынуть деньги из кармана* — кесәдән акча чыгару. ◇ **Вынь да положь** *разг.* — чыгар да сал; шушы минутта ук булсын, хәзер үк булсын.

**ВЫ'НУТЬСЯ** *сов.* — чыгу; *заноза вынулась* — шырпы чыкты.

**ВЫНЫ'РИВАТЬ** *несов.*— к. вынырнуть.

**ВЫ'НЫРНУТЬ** *сов.* — 1. *(из воды)* калкып чыгу, килеп чыгу; 2. *перен. разг.* *(внезап-*

*но появиться)* көтмәгәндә килеп чыгу, килеп чыгу.

**ВЫ'НЮХАТЬ** *сов. разг.*— **1.** иснәп бетерү (мәсәлән, борын тәмәкесен); **2.** *перен. (разузнать)* иснәнеп белү, сораштырып белү.

**ВЫНЮ'ХИВАТЬ** *несов. разг.*— к. вынюхать.

**ВЫНЯ'НЬЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. вынянчить.

**ВЫНЯ'НЬЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— тәрбияләп үстерелү, тәрбияләнү, карап үстерелү.

**ВЫ'НЯНЬЧИТЬ** *сов. разг.*— тәрбияләп үстерү, карап үстерү.

**ВЫ'ПАД** *м.*— **1.** *разг. (действие)* төшү, егылып төшү; *(о волосах)* коелу; **2.** *перен.* дошманлык чыгышы; *выпады реакционеров против сторонников мира не испугают народных масс* — реакционерларның тынычлыкны яклаучыларга каршы дошманлык чыгышлары халык массаларын куркыта алмас.

**ВЫПАДА'ТЬ** *несов.*— к. выпасть. ◇ **Выпадать из поля зрения** — күрми калу, истән чыгу.

**ВЫ'ПАЗИТЬ** *сов. спец.*—ырмау ую, ырмау уеп чыгу, ырмау ясау.

**ВЫПА'ИВАТЬ** I *несов.*— к. выпаять.

**ВЫПА'ИВАТЬ** II *несов. обл.*— к. выпоить.

**ВЫПА'ИВАТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. выпаяться; **2.** *страд.* эретеп куптарылу.

**ВЫ'ПАЛ** *м. простореч.*— ату, атып җибәрү.

**ВЫПА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. выпалить.

**ВЫ'ПАЛИТЬ** *сов. разг.*— 1. ату, атып җибәрү; *выпалить из ружья* — мылтыктан ату; **2.** *(неожиданно сказать)* әйтеп җибәрү, әйтеп ташлау, әйтеп салу; **3.** *обл. (выжечь)* яндырып бетерү.

**ВЫПА'ЛЫВАТЬ** *несов.*— к. выполоть.

**ВЫПА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— уталып бетү.

**ВЫПА'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. выпарить.

**ВЫПА'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. выпариться.

**ВЫ'ПАРИТЬ** *сов.*— **1.** пешекләү, парда тотып пешекләү; *выпарить бельё* — керне пешекләү; **2.** кайнатып табу; *выпарить соль* — кайнатып тоз табу; **3.** *(в бане)* чабындыру, мунча чабындыру.

**ВЫ'ПАРИТЬСЯ** *сов. разг.*—**1.** пешекләнү, парда тотып пешекләнү; **2.** *(о влаге)* парга әйләнеп бетү; **3.** *(в бане)* чабыну, мунча чабыну.

**ВЫПА'РХИВАТЬ** *несов.* — к. выпорхнуть.

**ВЫПА'РЫВАТЬ** *несов.*— к. выпороть I.

**ВЫПА'РЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— **1.** сүтеп алыну; **2.** эче алыну (суйган малның).

**ВЫ'ПАС** *м.*— **1.** *(пастьба)* көтү көтү, терлек көтү; **2.** *(пастбище)* көтүлек, утлавык, тибен.

**ВЫ'ПАСТИ** *сов. обл. с.-х.*— көтүлектә йөртеп ашату, көтүдә йөртү. ◇ **Выпасти луга** — көтү йөртеп болыннарны таптатып бетерү.

**ВЫ'ПАСТЬ** *сов.*— **1.** *(вывалиться)* төшү, егылып төшү, төшеп китү, төшеп калу; *(о волосах)* коелу; **2.** яву, төшү; *снег выпал* — кар яуды; **3.** туры килү, насыйп булу; *выпало мне счастье* — минем бәхетемә туры килде.

**ВЫ'ПАХАТЬ** *сов.* — сөрү, сукалау; сөреп чыгу, сөреп бетерү; *выпахать три гектара* — өч гектар сөрү. ◇ **Выпахал клад** — җир сөргәндә хәзинә тапкан. **Выпахать землю** — җирне искертү.

**ВЫ'ПАХАТЬСЯ** *сов. обл.*— сөргәндә килеп чыгу; *выпахался клад* — җир сөргәндә хәзинә килеп чыкты. ◇ **Этот участок совсем выпахался** — бу участок бөтенләй искереп беткән (уңыш бирми башлаган).

**ВЫПА'ХИВАТЬ** *несов. обл.*— к. выпахать.

**ВЫПА'ХИВАТЬСЯ** *несов. обл.*— **1.** к. выпахаться; **2.** *страд.* сөреп чыгылу, сөрелү; искертелү (җир турында).

**ВЫ'ПАЧКАТЬ** *сов. разг.*— пычрату, пычратып бетерү.

**ВЫ'ПАЧКАТЬСЯ** *сов. разг.*— пычрану, пычранып бетү.

**ВЫ'ПАЯТЬ** *сов. спец.*—эретеп алу, эретеп куптару (паять итеп ябыштырылган нәрсәне).

**ВЫ'ПАЯТЬСЯ** *сов. спец.* — эреп кубу, кубып төшү.

**ВЫПЕВА'ТЬ** *несов.*— к. выпеть.

**ВЫПЕКА'ТЬ** *несов.*— к. выпечь.

**ВЫПЕКА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. выпечься; **2.** *страд.* (берникадәр) пешереп чыгарылу; пешереп житкерелү.

**ВЫ'ПЕРЕТЬ** *сов. разг.*— к. выпирать 1, 2.

**ВЫ'ПЕСТОВАТЬ** *сов. поэт. ритор.*— үстерү, тәрбияләп үстерү; *партия выпестовала стойких, отважных борцов за дело коммунизма* —партия коммунизм эше өчен нык торучы батыр көрәшчеләр тәрбияләп үстерде.

**ВЫ'ПЕТЬ** *сов.*— **1.** тырышып-тырышып җырлау; тырышып-тырышып көйләү; **2.** *простореч.* әйтеп бирү, әйтеп салу; *я ему всю правду выпою* — мин аңа дөресен әйтеп бирермен.

**ВЫ'ПЕЧКА** *ж. мн.* нет — **1.** *только ед. (действие)* пешерү; *выпечка хлеба* — икмәк пешерү; **2.** *(то, что выпечено)* пешерелгән икмәк (яки башка берәр ашамлык); *привезли сегодняшнюю выпечку* — бүген пешерелгән икмәкне китерделәр; **3.** пешерелгән икмәк күләме.

**ВЫ'ПЕЧЬ** *сов.*— **1.** пешерү, пешереп чыгару; *пекарня выпекла за день 500 кг хлеба* — пекарня бер көн эчендә 500 *кг* икмәк пешереп чыгарды; **2.** *(пропечь)* пешереп житкерү.

**ВЫ'ПЕЧЬСЯ** *сов.*— пешеп житү, пешеп өлгерү (камыр ашамлыклар турында).

**ВЫПИВА'ЛА** *м. простореч. шутл.*— аракы мичкәсе (эчәргә ярата торган кеше).

**ВЫПИВА'ТЬ** *несов.*— 1. к. выпить; 2. *разг. (иметь склонность к выпивке)* эчкәләү.

**ВЫПИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— эчелү.

**ВЫ'ПИВКА** *ж. разг.*— 1. *(спиртной напиток)* эчемлек, исерткеч эчемлек; 2. *(попойка)* эчү мәҗлесе.

**ВЫ'ПИВШИ** — 1. эчкән килеш, эчеп; 2. *простореч фам.* исерек; *он был сильно выпивши* — ул бик нык исерек иде.

**ВЫПИ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. выпилить.

**ВЫПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— кисеп алыну, кисеп ясалу (пычкы белән).

**ВЫ'ПИЛИТЬ** *сов.*— кисеп алу, кисеп ясау (пычкы белән).

**ВЫПИРА'ТЬ** *несов. разг.*— 1. этеп чыгару, төртеп чыгару; *льдом выпирает дно бочки* — мичкәнең төбен боз этеп чыгара; 2. *(выдаваться вперёд)* алга чыгып тору; 3. *перен. (быть слишком заметным)* күзгә бәрелеп тору; 4. *вульг. (выгонять, увольнять)* куып чыгару.

**ВЫПИРА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— этеп чыгарылу, төртеп чыгарылу.

**ВЫ'ПИСАТЬ** *сов.*— 1. күчереп алу, язып алу, күчереп язып алу; *выписать несколько цитат* — берничә цитата күчереп алу; 2. *(написать полностью)* тулысынча язу; 3. чакырту, чакыртып алу; *выписать семью к себе* — семьяны үз янына чакыртып алу; 4. чыгару; *выписать больного из больницы* — авыруны больницадан чыгару; 5. язу, яздырып алу; *выписать чек* — чек язу (банктан акча алу өчен); 6. *(тщательно написать, нарисовать)* җентекләп язу, җентекләп төшерү. ◇ Выписать журнал — журналга язылу. Выписать книгу — китап соратып алу.

**ВЫ'ПИСАТЬСЯ** *сов.*— 1. чыгу, чыгып китү; *выписаться из больницы* — больницадан чыгу; 2. *устар. (исписаться)* язу сәләте бетү (язучылар турында).

**ВЫ'ПИСКА** *ж.*— 1. *только ед.* к. выписать 1, 2, 3, 5; 2. өземтә, цитата; *сделать выписки из книги* — китаптан өземтәләр алу; 3. күчермә; *выписка из приказа* — приказдан күчермә.

**ВЫПИСНО'Й** *устар.*—читтән китерелгән; *ткани выписные* — читтән китерелгән тукымалар.

**ВЫПИ'СЫВАТЬ** *несов.*— к. выписать.

**ВЫПИ'СЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. выписаться 1; 2. *страд.* күчереп алыну, күчереп язып алыну; тулысынча язылу; яздырылу; алдырылу; чакыртылу, чакыртып алыну; чыгарылу; язылу, язып алыну.

**ВЫ'ПИСЬ** *ж. офиц.*— к. выписка 3.

**ВЫ'ПИТЬ** *сов.*— эчү, эчеп бетерү.

**ВЫ'ПИХАТЬ** *сов. разг.*— к. выпихнуть.

**ВЫПИ'ХИВАТЬ** *несов. разг.*— к. выпихнуть.

**ВЫПИ'ХИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— төртеп чыгарылу, этеп чыгарылу, төрткәләп чыгарылу.

**ВЫ'ПИХНУТЬ** *сов. разг.*— төртеп чыгару, этеп чыгару, кысрыклап чыгару.

**ВЫ'ПЛАВИТЬ** *сов. спец.*— эретү, кою, эретеп алу, эретеп аеру (металлны); *выплавить 2 тонны чугуна* — ике тонна чуен кою.

**ВЫ'ПЛАВИТЬСЯ** *сов.*— коелу, эретелү, эретеп алыну (металл турында).

**ВЫ'ПЛАВКА** *ж.*— 1. *только ед. (действие)* эретү, кою (металлны); 2. эретелгән (коелган) металлның күләме; *суточная выплавка — 50 тонн стали* — тәүлек эчендә коелган корычның күләме — 50 тонна.

**ВЫПЛАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. выплавить.

**ВЫПЛАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. выплавиться.

**ВЫ'ПЛАВОК** *м.*— металл кисәге (рудадан эретеп алынган металл кисәге).

**ВЫ'ПЛАКАТЬ** *сов.*— 1. елап уртаклашу, елап җиңеләйтү, күз яше түгеп җиңеләйтү; *выплакать горе* — елап кайгыны уртаклашу; 2. *разг. (выпросить)* күз яше белән сорап алу, елап сорап алу, күз яше белән үтенеп алу. ◇ Выплакать глаза — 1. күп елап күзне шешендерү; елый-елый күзләрне бозу; 2. озак елау, күп елау.

**ВЫ'ПЛАКАТЬСЯ** *сов. разг.*—елап тынычлану, елап эч бушату.

**ВЫПЛА'КИВАТЬ** *несов.*— к. выплакать.

**ВЫ'ПЛАТА** *ж.*— 1. түләү; бирү; *выплата зарплаты* — эш хакы түләү; 2. азлапазлап түләү; *купил пальто на выплату* — азлап-азлап түләү шарты белән пальто алдым.

**ВЫ'ПЛАТИТЬ** *сов.*— түләү, түләп бетерү; *выплатить долги* — бурычларны түләп бетерү.

**ВЫПЛА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. выплатить.

**ВЫПЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— түләнү, бирелү.

**ВЫ'ПЛЕВАТЬ** *сов.*— төкереп ташлау.

**ВЫПЛЁВЫВАТЬ** *несов.*— к. выплевать.

**ВЫПЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— төкереп ташлану.

**ВЫ'ПЛЕСКАТЬ** *сов.*— чайкалдырып түгү, чайпалдырып түгү.

**ВЫ'ПЛЕСКАТЬСЯ** *сов.*— чайкалып түгелү, чайпалып түгелү.

**ВЫПЛЁСКИВАТЬ** *несов.*— к. выплескать.

**ВЫПЛЁСКИВАТЬСЯ** *несов.*— к. выплескаться.

**ВЫ'ПЛЕСНУТЬ** *однокр.*— түгеп җибәрү (чайкалдырып).

**ВЫ'ПЛЕСНУТЬСЯ** *однокр.*— түгелеп китү (чайпалып).

**ВЫ'ПЛЕСТИ** *сов.*— 1. сүтү (үрелгәнне), сүтеп алу; *выплести из косы ленту* — чәч толымыннан тасманы сүтеп алу; 2. үреп ясау, үреп әзерләү, бәйләп ясау; *выплести узор* — бәйләп бизәк ясау.

**ВЫ'ПЛЕСТИСЬ** *сов. разг.*—к. выплетаться.

**ВЫПЛЕТА'ТЬ** *несов.*— к. выплести.

**ВЫПЛЕТА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. сүтелү, сүтелеп төшү; 2. *страд.* сүтеп алыну; үрелү, үреп ясалу.

**ВЫ'ПЛУТАТЬСЯ** *сов. обл.*— ерынып чыгу, читенлек белән килеп чыгу, (адашкан җирдән) дөрес юлга чыгу.

**ВЫ'ПЛЫВ** *м. обл.*— к. выплывок.

**ВЫПЛЫВА'ТЬ** *несов.*— к. выплыть.◇ **Выплывать в памяти** — искә төшү, искә килү.

**ВЫ'ПЛЫВОК** *м. обл.* — 1. оры, агач шеше; 2. үсенте (ялгаган урыннан түбән үсеп чыккан ботак).

**ВЫ'ПЛЫТЬ** *сов.* — 1. *(всплыть на поверхность)* калку, калкып чыгу; 2. йөзеп чыгу; *выплыть из купальни* — купальнядан йөзеп чыгу; 3. *перен.* килеп чыгу, килеп басу; *выплыл ряд вопросов* — күп кенә мәсьәләләр килеп чыкты; 4. *перен. (избавиться от затруднений)* ерып чыгу.

**ВЫ'ПЛЮНУТЬ** *однокр.* — к. выплевать.

**ВЫПЛЯ'СЫВАТЬ** *несов.*— төрле фигуралар ясап бию.

**ВЫ'ПОИТЬ** *сов.*— эчереп үстерү, тәрбияләп үстерү; *выпоить телёнка молоком* — бозауны сөт эчереп үстерү.

**ВЫПОЛА'СКИВАТЬ** *несов.* — к. выполоскать.

**ВЫПОЛА'СКИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чайкалу, чайкап чистартылу.

**ВЫПОЛЗА'ТЬ** *несов.* — к. выползти. ◇ **Выползать наружу** — әкренләп ачылу, беленү (хурлыклы эшләр турында).

**ВЫ'ПОЛЗОК** *м. обл.* — 1. кабык (елан һәм башка шундыйларның салып ташлаган кабыгы); 2. *(червяк)* суалчан.

**ВЫ'ПОЛЗТИ** *сов.*— үрмәләп килеп чыгу, шуышып килеп чыгу, сөйрәлеп килеп чыгу; чыгу; *из щелей выползли тараканы* — ярыклардан тараканнар чыкты.

**ВЫ'ПОЛИРОВАТЬ** *сов. разг.* — шомартып ялтырату, полировать итү.

**ВЫПОЛНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(исполнение)* үтәү, башкару; 2. тутыру, үтәү, үтәлеш; *выполнение плана* — планны тутыру, планның үтәлеше.

**ВЫПОЛНИ'МЫЙ** — үтәлерлек, үти алырлык.

**ВЫ'ПОЛНИТЬ** *сов.*— 1. үтәү; *выполнить гражданский долг* — гражданлык бурычын үтәү; *выполнить пятилетку в четыре года* — бишьеллыкны дүрт елда үтәү; 2. тутыру; *выполнить план* — планны тутыру; 3. башкару; *выполнить роль женщины* — хатыннар ролен башкару (пьесада).

**ВЫ'ПОЛНИТЬСЯ** *сов.*— үтәлү, үтәлеп бетү, башкарылу.

**ВЫПОЛНЯ'ТЬ** *несов.*— к. выполнить.

**ВЫПОЛНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выполниться; 2. *страд.* үтәлү, тутырылу.

**ВЫ'ПОЛОСКАТЬ** *сов.* — 1. чайкау, чайкап алу; *выполоскать бельё* — кер чайкап алу; 2. чайкау, чайкап ташлау; *выполоскать рот* — авызны чайкап ташлау.

**ВЫ'ПОЛОСНУТЬ** *однокр. разг.*— чайкап алу, чайкап ташлау.

**ВЫ'ПОЛОТЬ** *сов.*— утау, утап чыгу, утап бетерү; *выполоть гряды* — түтәлләрне утап чыгу; *выполоть траву* — чүп үләнне утау (утап ташлау).

**ВЫ'ПОЛОТЬСЯ** *сов. обл.*— утауны бетерү, утауны төгәлләү.

**ВЫ'ПОРОТЬ** I *сов. разг.*— 1. сүтеп алу; *выпороть подкладку из пальто* — пальтоның эчен сүтеп алу; 2. эчен ярып әрчү.

**ВЫ'ПОРОТЬ** II *сов.*— *(высечь)* яру, кыйнап ташлау, чыбыклау, камчы белән кыйнау.

**ВЫ'ПОРХНУТЬ** *сов.*— 1. очып чыгу, пырхылдап очып чыгу; 2. *перен. разг. (выбежать лёгкой поступью)* тиз генә килеп чыгу, елт итеп килеп чыгу.

**ВЫ'ПОТЕТЬ** *сов.*— тирләү, бик нык тирләү; *больной выпотел* — авыру бик нык тирләде.

**ВЫ'ПОТРОШИТЬ** *сов.* — эчен тазарту, эчен әрчү (чистарту), эчен алу; *выпотрошить рыбу* — балыкның эчен чистарту.

**ВЫ'ПРАВИТЬ** *сов.* — 1. турайту, төзәйтү; *выправить погнувшуюся ложку* — кәкрәйгән кашыкны турайту; 2. *перен.* төзәтү, бетерү; *выправить недочёты механизма* — механизмдагы кимчелекләрне бетерү; 3. *устар.* юллап алу, алу; *выправить удостоверение личности* — таныклык язуы алу. ◇ **Выправить руку** — 1) кулны күнектерү (эшкә); 2) тайган кулны урынына утырту.

**ВЫ'ПРАВИТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(выпрямиться)* тураю, турылану, төзәю; 2. *(исправиться)* төзәлү, яхшыру.

**ВЫПРАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. выправить 1, 3.

**ВЫПРАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выправиться; 2. *страд.* турайтылу, төзәйтелү; төзәтелү.

**ВЫПРА'СТЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. выпростать.

**ВЫПРА'СТЫВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. выпростаться.

**ВЫПРА'ШИВАТЬ** *несов.*— к. выпросить.

**ВЫПРА'ШИВАТЬСЯ** *несов.*— к. выпроситься.

**ВЫПРЕВА'ТЬ** *несов. просторес.*— к. выпреть.

**ВЫ'ПРЕТЬ** *сов.* — 1. *с.-х.* бурсып черү, тончыгып черү (кар астында уҗым); 2. *просторец.* кайнап бетү; *суп почти весь выпрел* — аш бөтенләй диярлек кайнап беткән.

**ВЫПРОВА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. выпроводить.

**ВЫПРОВА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— куып чыгарылу, куылу; чыгарып җибәрелү, куып җибәрелү; этә-төртә чыгарылу.

**ВЫ'ПРОВОДИТЬ** *сов. разг. пренебр.*— чыгарып җибәрү, куып җибәрү, куып чыгару, этә-төртә чыгару.

**ВЫ'ПРОСИТЬ** *сов.* — сорап алу, үтенеп сорап алу, ялынып-ялварып алу.

**ВЫ'ПРОСИТЬСЯ** *сов.*— сорап китү, китәргә рөхсәт алу.

**ВЫ'ПРОСТАТЬ** *сов. просторец.*— 1. бушату; *выпростай корзину* — кәрзинне бушат; 2. чыгару; *выпростать руки из-под одеяла* — кулларны одеял астыннан чыгару.

**ВЫ'ПРОСТАТЬСЯ** *сов. простореч.* — бушау, бушап калу.

**ВЫПРЫ'ГИВАТЬ** *несов.* — к. выпрыгнуть.

**ВЫ'ПРЫГНУТЬ** *сов.* — сикереп чыгу; *выпрыгнуть из окна* — тәрәзәдән сикереп чыгу; *выпрыгнуть из-за куста* — куак артыннан сикереп чыгу.

**ВЫ'ПРЫСКАТЬ** *сов. разг.* — бөркеп бетерү, сибеп бетерү.

**ВЫПРЫ'СКИВАТЬ** *несов. разг.* — к. выпрыскать.

**ВЫПРЫ'СКИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — сибеп бетерелү, бөркеп бетерелү.

**ВЫ'ПРЫСНУТЬ** *однокр. разг.* — бөркеп алу, сибеп алу. ◇ **Выпрыснуть из комнаты** — бүлмәдән атылып чыгып китү.

**ВЫПРЯГА'ТЬ** *несов.* — к. выпрячь.

**ВЫПРЯГА'ТЬСЯ** *несов.* — к. выпрячься.

**ВЫ'ПРЯМИТЬ** *сов.* — турылау, турайту, төзәйтү.

**ВЫ'ПРЯМИТЬСЯ** *сов.* — 1. тураю; 2. туптуры басу.

**ВЫПРЯМЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. выпрямить.

**ВЫПРЯМЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выпрямиться; 2. *страд.* турайтылу, төзәйтелү.

**ВЫ'ПРЯСТЬ** *сов.* — эрләү, эрләп кую.

**ВЫ'ПРЯЧЬ** *сов.* — туару.

**ВЫ'ПРЯЧЬСЯ** *сов.* — туарылу.

**ВЫПУ'ГИВАТЬ** *несов. разг.* — к. выпугнуть.

**ВЫПУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — куркытып чыгарылу.

**ВЫ'ПУГНУТЬ** *сов. разг.* — куркытып чыгару.

**ВЫ'ПУКЛО** *нареч. перен.* — кабарынкы итеп, калку итеп, ачык итеп, күзгә ташланырлык итеп; *в романе выпукло даны образы героев* — романда геройларның образлары ачык итеп бирелгән.

**ВЫ'ПУКЛО-ВО'ГНУТЫЙ** *физ.* — кабарынкы-батынкы (бер ягы кабарынкы, бер ягы батынкы); *выпукло-вогнутое стекло* — кабарынкы-батынкы пыяла.

**ВЫ'ПУКЛОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед. (качество)* кабарынкылык; 2. *(выпуклое место)* кабарынкы урын, калку урын; 3. *только ед. перен.* ачыклык, аныклык; *выпуклость художественного образа* — художество образының ачыклыгы.

**ВЫ'ПУКЛЫЙ** — 1. кабарынкы; *выпуклое стекло* — кабарынкы пыяла; 2. чыгып тора торган, кабарынкы; *выпуклые буквы* — чыгып тора торган хәрефләр; 3. *перен.* ачык, күзгә ташланырлык, күзгә бәрелерлек; *выпуклое изображение героев* — геройларны күзгә ташланырлык итеп сурәтләү. ◇ **Выпуклый лоб** — чыгынкы маңгай.

**ВЫ'ПУСК** *м.* — 1. *только ед. (действие)* чыгару; *выпуск займа* — заём чыгару; *(о продукции)* эшләп чыгару; *(об изданиях)* бастырып чыгару; 2. чыгарылыш; *выпуск учащихся* — укучылар чыгарылышы; 3. кыскарту, төшереп калдыру; *роман издан с выпусками* — роман кыскартулар белән басылган. ◇ **Брюки на выпуск** — балагы чыгарып киелә торган чалбар.

**ВЫПУСКА'ТЬ** *несов.* — к. выпустить.

**ВЫПУСКА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. чыгарылу, чыгарып җибәрелү; 2. эшләп чыгарылу; бастырып чыгарылу; 3. төшереп җибәрелү, ычкындырып җибәрелү; 4. чыгарылу, хәзерләп чыгарылу; 5. төшереп калдырылу; 6. агызылу; 7. *портн.* киңәйтелү, озынайтылу, җибәрелү.

**ВЫПУСКНИ'К** *м.*, **ВЫПУСКНИ'ЦА** *ж.* — тәмамлаучы (мәктәпне яки башка уку йортын), соңгы класста укучы, соңгы курста укучы.

**ВЫПУСКНО'Й** — 1. чыгару...-ы, чыгарыш ...-ы; *выпускные экзамены* — чыгарыш имтиханнары; 2. тәмамлаучылар...-ы; *выпускная группа* — тәмамлаучылар группасы; 3. *тех.* чыгара торган, чыгару...-ы; *выпускное отверстие доменной печи* — домна миченең чыгара торган тишеге; 4. *торг.* сату...-ы; *выпускная цена товаров* — товарларның сату бәясе.

**ВЫ'ПУСТИТЬ** *сов.* — 1. чыгару, чыгарып җибәрү; *выпустить птицу на свободу* — кошны ireккә чыгару; 2. чыгару; эшләп чыгару; *выпустить товары высокого качества* — югары сыйфатлы товарлар эшләп чыгару; 3. басып чыгару; бастырып чыгару; *выпустить книгу* — китап басып чыгару; 4. төшереп җибәрү, ычкындырып җибәрү; *выпустить из рук стакан* — кулдан стаканны төшереп җибәрү; 5. чыгару, хәзерләп чыгару; *выпустить из института специалистов* — институттан белгечләр хәзерләп чыгару; 6. төшереп калдыру; *выпустить вторую главу* — икенче бүлекне төшереп калдыру; 7. агызу; *выпустить воду из бочки* — мичкәдән суны агызу; 8. *портн.* киңәйтү, озынайту, җибәрү; *выпустить рукава* — җиңне озынайту. ◇ **Выпустить из виду** — оныту, игътибарга алмау (берәр нәрсәне).

**ВЫ'ПУТАТЬ** *сов. разг.* — 1. чуалганны, чияләнгәнне сүтү; 2. *перен.* коткару, йолып алу.

**ВЫ'ПУТАТЬСЯ** *сов.* — 1. *(освободиться от пут)* тышаудан ычкыну; 2. *перен.* ерылып чыгу, котылу; *выпутаться из затруднительного положения* — авыр хәлдән ерылып чыгу.

**ВЫПУ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. выпутать.

**ВЫПУ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выпутаться; 2. *страд.* сүтеп алыну; 3. *перен. страд.* коткарылу, йолып алыну.

**ВЫПУ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. выпучить.

**ВЫПУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — к. выпучиться.

**ВЫ'ПУЧИТЬ** *сов. простореч.* — 1. акайту, чекрәйтү; *выпучить глаза* — күзләрне акайту, күзләрне чекрәйтү; 2. кабарту; киерү; *выпучить живот* — корсакны киерү.

**ВЫ'ПУЧИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. акаю, чекрәю; *глаза выпучились* — күзләре чекрәйгән (акайган); 2. киерелү, бүлтәю; *живот выпучился* — корсагы киерелгән.

**ВЫ'ПУШИТЬ** *сов. портн.* — кырпу тоту, кама тоту (мәсәлән, бүрек кырыена).

**ВЫ'ПУШКА** *ж.*— кырпу, кама (кием кырыена тотылган мех).

**ВЫ'ПЫТАТЬ** *сов.* — сорашып белү, әйттерү, көчләп әйттерү, әйтергә мәҗбүр итү (серне, гаепне); *выпытать правду* — дөресләкне әйттерү.

**ВЫПЫ'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. выпытать.

**ВЫПЫ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сорашып беленү, көчләп әйттерелү (сер, гаеп турында).

**ВЫПЬ** *ж. зоол.*— күлбога (челәнчәләр семьялыгыннан бер кош).

**ВЫПЯ'ЛИВАТЬ** *несов. разг. вульг.* — к. выпялить.

**ВЫПЯ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. разг. вульг.*— к. выпялиться.

**ВЫ'ПЯЛИТЬ** *сов. разг. вульг.*— 1. киерү; бүлтәйтү; *выпялить живот* — корсакны киерү; 2. акайту, чекрәйтү; *выпялить глаза* — күзне акайту, күзне чекрәйтү.

**ВЫ'ПЯЛИТЬСЯ** *сов. разг. вульг.*— 1. сузылу; *выпялиться из окна* — тәрәзәдән сузылу; 2. алга чыгып тору.

**ВЫ'ПЯТИТЬ** *сов.* — 1. алга чыгару, киерү; *выпятить грудь* — күкрәкне киерү; 2. *перен.* кабартып кую, күпертеп кую; *выпятить вопрос* — мәсьәләне кабартып кую.

**ВЫ'ПЯТИТЬСЯ** *сов. просторeч.* — алга чыгып тору; киерелү.

**ВЫПЯ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. выпятить.

**ВЫПЯ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. выпятиться; 2. *страд.* алга чыгарылу; кабартылу, күпертелү.

**ВЫРАБА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. выработать.

**ВЫРАБА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. эшләп чыгарылу, житештерелү; 2. хәзерләнү; 3. тәрбияләнү, булдырылу; 4. эшләнү, эшләп табылу.

**ВЫ'РАБОТАТЬ** *сов.* — 1. *(произвести)* эшләп чыгару, житештерү; 2. хәзерләү; *выработать резолюцию* — резолюция хәзерләү; 3. тәрбияләү, булдыру; *выработать в себе силу воли* — үзендә ихтыяр көче булдыру; 4. *спорт.* өйрәтү, күнектерү, гадәтләндерү; *выработать лошадь* — атны өйрәтү (гадәтләндерү); 5. *просторeч.* эшләп табу, эшләү; *за неделю выработал десять трудодней* — бер атна эчендә ун хезмәт көне эшләде.

**ВЫ'РАБОТКА** *ж.*— 1. *только ед. (действие)* к. выработать; 2. *(готовая продукция)* эшләп чыгарылган продукция, әзер продукция; 3. эшләнеш, сыйфат; *продукция хорошей выработки* — яхшы эшләнешле (сыйфатлы) продукция.

**ВЫРА'ВНИВАТЬ** *несов.*— к. выровнять.

**ВЫРА'ВНИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. выровняться; 2. *страд.* тигезләндерелү, такырайтылу.

**ВЫРАЖА'ТЬ** *несов.* — 1. әйтү, белдерү, аңлату; *выражать своё недовольство* — үзенең ризасызлыгыңны белдерү; 2. чагылдыру, гәүдәләндерү; *картина выражает замыслы художника* — картина художникның уйларын гәүдәләндерә (чагылдыра); 3. *спец.* күрсәтү, исәпләү; *выражать в цифрах* — цифрлар белән күрсәтү; *выражать в метрических мерах* — метр үлчәүләре белән исәпләү. ◇ **Выражать собою** — белдерү.

**ВЫРАЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *страд.* әйтелү, аңлатылу, белдерелү; чагылдырылу, гәүдәләндерелү, күрсәтелү; 2. гыйбарәт булу, тору; *в чём выражается ваше участие?* — сезнең катнашыгыз нәрсәдән гыйбарәт? 3. сөйләү; *он выражается книжно* — ул китапча сөйли; 4. *просторeч. (браниться)* сүгенү, әдәпсез сүзләр әйтү.

**ВЫРАЖЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед. (действие)* к. выражать; 2. әйтем, сүзләр; *образное выражение* — образлы әйтем; *непонятное выражение* — аңлаешсыз сүзләр, аңлаешсыз әйтем; 3. *мат.* аңлатма; *алгебраическое выражение* — алгебраик аңлатма. ◇ **Выражение лица** — чырай. **Выражение глаз** — күз карашы. **Читать с выражением** — ачык итеп, тәэсир калдырырлык итеп уку. **По выражению** — әйткәнчә, әйтмешли.

**ВЫ'РАЖЕННЫЙ** — 1. әйтелгән, белдерелгән; аңлатылган; *мысль, выраженная словами* — сүзләр белән әйтелгән фикер; 2. гәүдәләнгән, гәүдәләндерелгән; күрсәтелгән; 3. күренеп тора торган; *ярко выраженный классовый характер* — ачык күренеп тора торган сыйнфый характер.

**ВЫРАЗИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ВЫРАЗИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — чагылдыручы, гәүдәләндерүче; *выразитель воли масс* — массаларның ихтыярын гәүдәләндерүче.

**ВЫРАЗИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — ачык итеп, тәэсирле итеп; *выразительно читать* — тәэсирле итеп уку.

**ВЫРАЗИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәэсирлелек, тәэсир итүчәнлек.

**ВЫРАЗИ'ТЕЛЬНЫЙ** — мәгънәле, тәэсирле; *выразительные глаза* — тәэсирле күзләр; *выразительный взгляд* — мәгънәле караш. ◇ **Выразительное чтение** — нәфис уку, сәнгатьле уку.

**ВЫ'РАЗИТЬ** *сов.*— к. выражать.

**ВЫ'РАЗИТЬСЯ** *сов.*— 1. күренү; *трудовой героизм выразился в дальнейшем росте продукции* — хезмәттәге геройлык продукция чыгаруның үсә баруында күренде; 2. әйтү; *если так можно выразиться* — әгәр болай дип әйтергә мөмкин булса.

**ВЫРАСТА'ТЬ** *несов.*— к. вырасти.

**ВЫ'РАСТИ** *сов.* — 1. үсү; үсеп житү; 2. *перен. (увеличиться)* көчәю, үсү; 3. күренү, күз алдына килеп басу; *вдали выросли горы* — ерактан таулар күренде; 4. үсү, күтәрелү; *молодой писатель значительно вырос* — яшь язучы шактый үсте. ◇ **Девочка выросла из платья** — кыз баланың күлмәге кечерәйде (кыскарды, тарайды, сыймый башлады — үсү аркасында). **Вырасти** *в чьих-либо* **глазах** — кемнең дә булса каршында дәрәҗәсе күтәрелү. **Вырасти из-под земли** — көтмәгәндә килеп чыгу.

**ВЫ'РАСТИТЬ** *сов.* — үстерү; тәрбияләп үстерү, карап үстерү.

**ВЫРА'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. вырастить.

**ВЫРА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — үстерелү, тәрбияләп үстерелү, карап үстерелү.

**ВЫ'РВАТЬ** I *сов.* — 1. өзеп алу, йолкып алу; *вырвать сорняки* — чүп үләннәрне өзеп алу (йолкып алу); 2. тартып алу; *вырвать письмо из рук* — хатны кулдан тартып алу; 3. суыру, суырып алу, суыр-ту; *вырвать больной зуб* — авыру тешне суыру; 4. ертып алу; *вырвать страницу из книги* — китап битен ертып алу; 5. *перен.* мәҗбүр итү; *вырвать признание вины* — гаебен тануга мәҗбүр итү.

**ВЫ'РВАТЬ** II *сов. безл. разг.* — косу.

**ВЫ'РВАТЬСЯ** *сов.* — 1. ертылып төшү, өзелеп төшү; *из книги вырвалась страница* — китапның бер бите ертылып төшкән; 2. котылу, котылып чыгу; *вырваться из вражеского окружения* — дошман камавыннан котылып чыгу; 3. ычкынып китү; төшеп китү; *стакан вырвался из рук* — стакан кулдан төшеп китте; 4. атылып чыгу; *пламя вырвалось из трубы* — ялкын морҗадан атылып чыкты. ◇ **Вырвалось неосторожное слово** — кирәкмәс сүз ычкынып китте. **Река вырвалась из берегов** — елга ярларыннан чыккан. **Вырвалось признание** — көтмәгәндә әйтеп бирде, көтмәгәндә икърар итте.

**ВЫ'РЕЗ** *м.* — 1. *(то, что вырезано)* уеп (яки кисеп) алынган әйбер; 2. *(вырез у платья)* уем, уемты. ◇ **Покупать на вырез** — кисеп карап алу (мәсәлән, карбызны).

**ВЫ'РЕЗАТЬ** *сов.* — 1. *(разрезая, вынуть)* кисеп алу, уеп алу; 2. чокып ясау, чокып язу, чокып төшерү; *вырезать своё имя на кольце* — балдакка үзеннең исемеңне чокып язу; 3. үтереп бетерү, кырып бетерү; *фашисты вырезали целые деревни* — фашистлар бөтен-бөтен авылларны кырып бетерделәр; 4. *(выделить межеванием)* кисеп бирү, бүлеп бирү, аерып бирү.

**ВЫРЕЗА'ТЬ** *несов.* — к. вы́резать.

**ВЫ'РЕЗАТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг. (посредством вырезания отделиться)* кисеп алыну, уеп алыну; 2. *разг. (изготовиться посредством вырезки)* киселү, кисеп ясалу; 3. *перен.* ачык булып күренү; *на фоне заката вырезались верхушки деревьев* — шәфәкъ нурлары фонында агач башлары ачык булып күренде.

**ВЫРЕЗА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. вы́резаться; 2. *страд.* чокып ясалу, чокып төшерелү, чокып язылу.

**ВЫ'РЕЗКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. вы́резать 1, 2, 4; 2. кисемтә (кисеп алынган нәрсә, кисеп алынган урын); *вырезки из газет* — газеталардан кисемтәләр; 3. *(лучшая часть филе)* билдәмә.

**ВЫРЕ'ЗЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. выреза́ть.

**ВЫРЕ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. вырезаться.

**ВЫРЕША'ТЬ** *несов.* — к. вырешить.

**ВЫРЕША'ТЬСЯ** *несов.* — к. вырешиться.

**ВЫ'РЕШИТЬ** *сов.* — хәл итү, хәл кылу, чишү, чишеп бетерү (берәр мәсьәләне).

**ВЫ'РЕШИТЬСЯ** *сов.* — хәл ителү, хәл кылыну, чишелү, чишелеп бетү.

**ВЫ'РИСОВАТЬ** *сов.* — бик җентекләп рәсем ясау.

**ВЫ'РИСОВАТЬСЯ** *сов.* — күренү, ачык булып күренү.

**ВЫРИСО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. вырисовать.

**ВЫРИСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. вырисоваться.

**ВЫ'РОВНИТЬ** *сов.* — к. выровнять.

**ВЫ'РОВНИТЬСЯ** *сов.* — к. выровняться.

**ВЫ'РОВНЯТЬ** *сов.* — 1. тигезләү, такыргайту; *выровнять дорогу* — юлны тигезләү; 2. турылау, тигезләү; *выровнять шеренгу* — сафны турылау. ◇ **Выровнять слог** *устар.* — стильне төзәтү, шомарту.

**ВЫ'РОВНЯТЬСЯ** *сов.* — 1. тигезләнү, такыраю; *дорога выровнялась* — юл тигезләнде; 2. тигезләнү; *ряды выровнялись* — сафлар тигезләнде; 3. *перен.* төзәлү, яхшыру; *характер у него выровнялся* — аның холкы яхшырды. ◇ **Мальчик выровнялся с классом** — малай классны куып җитте.

**ВЫ'РОДИТЬСЯ** *сов.* — 1. *(ухудшиться в природе)* сыйфаты начарлану; 2. *перен.* әверелү; *оппортунисты выродились в прямых агентов империализма* — оппортунистлар империализмның турыдан-туры агентларына әверелделәр.

**ВЫ'РОДОК** *м. разг.* — адәм хуры, адәм калдыгы, адәм актыгы.

**ВЫРОЖДА'ТЬСЯ** *несов.* — к. выродиться.

**ВЫРОЖДЕ'НЕЦ** *м.* — к. выродок.

**ВЫРОЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(ухудшение породы, потеря внешних признаков)* токым начарлану, токым бозылу, нәсел бозылу; *(о растении)* сорты бозылу, сорты начарлану; 2. *перен.* бетүгә йөз тоту; *вырождение буржуазной культуры* — буржуаз культураның бетүгә йөз тотуы.

**ВЫ'РОИТЬСЯ** *сов.* — ил аеру; күч аерылып чыгу (умарта кортлары турында).

**ВЫ'РОНИТЬ** *сов.* — төшереп җибәрү; төшереп калдыру, төшереп югалту.

**ВЫ'РОСТ** *м. мн.* нет — оры, чыгынты.

**ВЫ'РОСТКОВЫЙ** — 1. бозау күненнән тегелгән; *выростковые сапоги* — бозау күненнән тегелгән итек; 2. *обл.* яшүсмерләр...-ы; *выростковая группа* — яшүсмерләр группасы.

**ВЫ'РОСТОК** *м.* — 1. *обл.* йорт тумасы (йортта тәрбияләп үстерелгән хайван); 2. *спец.* бозау тиресе; шундый тиредән иләнгән күн; 3. *обл. (ребёнок подросток)* яшүсмер.

**ВЫ'РУБ** *м. обл.* — 1. кисенте (агачлары киселгән урман урыны); 2. уемты (уеп алынган урын).

**ВЫРУБА'ТЬ** *несов.* — к. вырубить.

**ВЫРУБА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. вырубиться; 2. *страд.* уеп ясалу, уелу,

**ВЫ'РУБИТЬ** *сов.* — 1. кисеп бетерү; *вырубить рощу* — куаклыкны кисеп бетерү; 2. ую, уеп ясау; *вырубить окно* — тәрәзә ую.

**ВЫ'РУБИТЬСЯ** *сов.* — 1. килеп чыгу (кисеп ясау нәтиҗәсендә); 2. кисеп юл ачып чыгу; *с трудом вырубились из чащи леса* — куе урманнан агачларны кисеп юл ачып чыктык.

**ВЫ'РУГАТЬ** *сов. разг.* — сүгеп ташлау, әрләп ташлау.

**ВЫ'РУГАТЬСЯ** *сов. разг.* — сүгенеп кую.

**ВЫРУЧА'ТЬ** *несов.* — к. выручить.

**ВЫРУЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — коткарылу, котылдырылу, йолыну, йолып алыну.

**ВЫ'РУЧИТЬ** *сов.* — коткару, котылдыру, йолып алу, булышу; *выручить из беды* — бәладән коткару; 2. ... сумлык сату, ... сум чыгару; *продавец выручил за день... рублей* — сатучы бер көн эчендә ... сумлык товар сатты; 3. кире кайтару; *я свои деньги выручил* — мин үз акчамны кире кайтардым.

**ВЫ'РУЧКА** *ж.* — 1. *только ед.* коткару, йолып алу, булышу, ярдәм итү; *он пошел на выручку товарищей* — ул иптәшләрен коткарырга китте; 2. (*деньги, полученные от торговли*) керем, выручка.

**ВЫРЫВА'ТЬ** I *несов.* — к. вырвать I.

**ВЫРЫВА'ТЬ** II *безл. многокр. просторечн.* — костыру, косу.

**ВЫРЫВА'ТЬ** III *несов.* — к. вырыть.

**ВЫРЫВА'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. вырваться; 2. *страд.* суырылу, суырып чыгарылу, куптарып чыгарылу.

**ВЫРЫВА'ТЬСЯ** II *несов.* — 1. *разг.* к. вырыться; 2. *страд.* казылу.

**ВЫ'РЫТЬ** *сов.* — 1. казу; *вырыть колодец* — кое казу; 2. казып алу, казып чыгару; *вырыть камень* — таш казып чыгару; 3. *перен. разг.* казынып табу, эзләп табу; *в архиве он вырыл важные документы* — архивтан ул мөһим документлар эзләп тапкан.

**ВЫ'РЫТЬСЯ** *сов. разг.* — казып чыгу, казып килеп чыгу; *крот вырылся на поверхность* — сукыр тычкан җир өстенә казып чыккан.

**ВЫ'РЯДИТЬ** *сов.* — киендерү, матур итеп киендерү, купшы итеп киендерү.

**ВЫ'РЯДИТЬСЯ** *сов.* — киенү, матур итеп киенү, купшы итеп киенү.

**ВЫРЯЖА'ТЬ** *несов. разг.* — к. вырядить.

**ВЫРЯЖА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. вырядиться; 2. *страд.* матур итеп киендерелү, купшы итеп киендерелү.

**ВЫ'САДИТЬ** *сов.* — 1. төшерү; *высадить ребёнка из коляски* — баланы арбасыннан төшерү; *высадить десант* — десант төшерү; 2. күчереп утырту; *высадить растения из парников на гряды* — үсемлекләрне парниклардан түтәлләргә күчереп утырту; 3. *разг. вульг.* бәреп чыгару, ватып чыгару, вату; *высадить дверь* — ишекне бәреп чыгару.

**ВЫ'САДИТЬСЯ** *сов.* — төшү, чыгу; *на берег высадились десантные войска* — ярга десант гаскәрләре төште; *я высадился из лодки на берег* — мин көймәдән ярга чыктым.

**ВЫ'САДКА** *ж.* — 1. *только ед.* чыгару, төшерү; *высадка десанта* — десант төшерү; 2. *только ед.* (*о растениях*) күчереп утырту, чыгарып утырту; 3. *только мн.* утыртылган үсемлекләр; *семенные высадки* — орлык өчен утыртылган үсемлекләр.

**ВЫСА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. высадить.

**ВЫСА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. высадиться; 2. *страд.* чыгарылу, төшерелү; (*о растениях*) күчереп утыртылу, чыгарып утыртылу.

**ВЫСА'ЛИВАТЬ** I *несов. простореч.* — к. высалить.

**ВЫСА'ЛИВАТЬ** II *несов. разг.* — к. высолить.

**ВЫСА'ЛИВАТЬСЯ** I *несов. простореч.* — 1. к. высалиться; 2. *страд.* майландырылу, майландырып бетерелү.

**ВЫСА'ЛИВАТЬСЯ** II *несов. страд.* — тозлану.

**ВЫ'САЛИТЬ** *сов. простореч.* — майландыру, майга буяп бетерү.

**ВЫ'САЛИТЬСЯ** *сов. простореч.* — майга буялу, майланып бетү.

**ВЫСА'СЫВАТЬ** *несов.* — к. высосать.

**ВЫСА'СЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — суырылу, суырып чыгарылу, суырып бетерелү.

**ВЫСА'ЧИВАТЬ** *несов. разг. спец.* — к. высочить.

**ВЫСА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг. спец.* — 1. к. высочиться; 2. *страд.* суы (сүле) чыгарылу, согы чыгарылу.

**ВЫ'СВАТАТЬ** *сов. разг. устар.* — кыз ярәшү.

**ВЫСВА'ТЫВАТЬ** *несов. разг. устар.* — к. высватать.

**ВЫ'СВЕЖЕВАТЬ** *сов. спец.* — тунау, эчен алу, тазарту, чистарту (суйган хайван турында).

**ВЫСВЕ'РЛИВАТЬ** *несов.* — к. высверлить.

**ВЫСВЕ'РЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. высверлиться.

**ВЫ'СВЕРЛИТЬ** *сов.* — бораулап тишү, бораулап тишеп чыгару.

**ВЫ'СВЕРЛИТЬСЯ** *сов.* — борау белән тишелү.

**ВЫ'СВИСТАТЬ, ВЫ'СВИСТЕТЬ** *сов. простореч.* — 1. сызгырып көй чыгару; 2. сызгырып чакыру.

**ВЫСВИ'СТЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. высвистать.

**ВЫСВИ'СТЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — 1. сызгырып көй чыгарылу; 2. сызгырып чакырылу.

**ВЫ'СВОБОДИТЬ** сов. — 1. ычкындыру, чыгару; *еле высвободил ногу из стремени* — аягымны өзәңгедән чак кына ычкындырдым; 2. коткару, азат итү, иреккә чыгару; *высвободить революционера из тюрьмы* — революционерны төрмәдән азат

итү; 3. бушату; *высвободить часть оборотных средств* — оборотта йөри торган средстволарның бер өлешен бушату.

**ВЫ'СВОБОДИТЬСЯ** *сов.* — чыгу, ычкынып чыгу; *нога его высвободилась из стремени* — аның аягы өзәңгедән чыкты.

**ВЫСВОБОЖДА'ТЬ** *несов.* — к. высвободить.

**ВЫСВОБОЖДА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. высвободиться; 2. *страд.* чыгарылу; бушатылу; коткарылу, азат ителү, ирекка чыгарылу.

**ВЫ'СЕВ** *м. с.-х.* — чәчү; *норма высева* — чәчү нормасы.

**ВЫСЕВА'ТЬ** *несов.* — к. высеять.

**ВЫСЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — чәчелү, чәчүгә тотылу.

**ВЫ'СЕВКИ** *ед.* нет — көрпә, иләк өсте (иләк өстендә калган он һ. б.).

**ВЫСЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. высеять.

**ВЫСЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. высеваться.

**ВЫСЕКА'ТЬ** *несов.* — 1. чокып язу; *высекать надписи на камне* — чокып ташка язу язу; 2. чокып ясау; *скульптор высекает из мрамора статую* — скульптор мрамордан чокып статуя (сын) ясый. ◇ **Высекать огонь** — ут чыгару (чакма таштан).

**ВЫСЕКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. (*о волосах*) коелу; (*о нитках*) сыпылу, сыпылып чыгу; 2. *страд.* (*о статуе*) чокып ясалу; (*о письме*) чокып язылу.

**ВЫСЕЛЕ'НЕЦ** *м.*, **ВЫСЕЛЕ'НКА** *ж.* — күчерелгән кеше; күчеп киткән кеше.

**ВЫ'СЕЛИТЬ** *сов.* — 1. чыгару; *выселить из квартиры* — квартирадан чыгару; 2. икенче җиргә күчерү.

**ВЫ'СЕЛИТЬСЯ** *сов.* — күчү, күчеп китү; *скоро мы выселимся отсюда* — тиздән без моннан күчеп китәрбез.

**ВЫ'СЕЛОК** *м.* — пучинкә, яңа авыл (зур авылдан күчеп утырган яңа авыл).

**ВЫСЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. выселить.

**ВЫСЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. выселиться; 2. *страд.* чыгарылу, куып чыгарылу, сөрелү.

**ВЫ'СЕМЕНИТЬСЯ** *сов.* — орлыгы коелу; *траву косят, когда она ещё не высеменилась* — үләнне орлыгы коелмас борын чабалар.

**ВЫ'СЕРЕБРИТЬ** *сов.* — көмешләү, көмеш йөгертү, көмеш йөгертеп чыгу.

**ВЫ'СЕЧЬ** I. *сов.* — 1. к. высекать; 2. чыгару; *высечь искру из камня* — таштан очкын чыгару.

**ВЫ'СЕЧЬ** II *сов.* — яру, чыбыклау, суктыру, кыйнау (чыбык яки камчы белән).

**ВЫ'СЕЧЬСЯ** *сов. разг.* — (*о волосах*) коелу; (*о нитках*) сыпылу, сыпылып чыгу.

**ВЫ'СЕЯТЬ** *сов. с.-х.* — чәчү, чәчүгә тоту.

**ВЫ'СИДЕТЬ** *сов.* — 1. утыру, утырып үткәрү (билгеле бер вакытны); *он высидел целую неделю дома* — ул бер атна буена өйдә утырды; 2. чыгару; *курица высидела цыплят* — тавык чебиләр чыгарды.

**ВЫ'СИДЕТЬСЯ** *сов.* — 1. *просторен.* утыру, утырып үткәрү; *после болезни пришлось высидеться дома* — авырудан соң өйдә утырып үткәрергә туры килде; 2. *обл.* (*о птицах*) утыра-утыра ябыгып бетү.

**ВЫСИ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. высидеть.

**ВЫСИ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. высидеться; 2. *страд.* (*о птенцах*) чыгарылу.

**ВЫ'СИНИТЬ** *сов. просторен.* — 1. (*о белье*) синькалау; 2. (*закрасить синей краской*) зәңгәргә буяу, зәңгәргә ману.

**ВЫ'СИНИТЬСЯ** *сов. просторен.* — 1. синькалану; 2. зәңгәр буяуга буялу, зәңгәр төскә буялу, зәңгәргә буялу.

**ВЫ'СИТЬСЯ** *несов.* — биегәеп тору, өскә чыгып тору, калкып тору; *на берегу озера высилась башня* — күл буенда башня калкып тора иде.

**ВЫСКА'БЛИВАТЬ** *несов.* — к. выскоблить.

**ВЫСКА'БЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. кырып алыну, кырып ташлану; 2. кырып шомартылу.

**ВЫ'СКАЗАТЬ** *сов.* — әйтү, әйтеп бирү, әйтеп бетерү; *высказать своё мнение* — үз фикерен әйтү.

**ВЫ'СКАЗАТЬСЯ** *сов.* — фикер әйтү; сөйләү; *он высказался о проекте* — проект турында ул үз фикерен әйтте; *высказались два человека* — ике кеше сөйләде.

**ВЫСКА'ЗЫВАНИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* әйтү, әйтеп бирү; *высказывание своего мнения* — үз фикерен әйтеп бирү; 2. (*мнение*) фикер, әйтелгән сүз, әйткәннәр; *высказывания классиков марксизма-ленинизма* — марксизм-ленинизм классикларының әйткәннәре.

**ВЫСКА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. высказать.

**ВЫСКА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. высказаться; 2. *страд.* әйтелү, сөйләнү; *высказываются смелые суждения* — кыю фикерләр әйтелә.

**ВЫ'СКАКАТЬ** *сов. просторен.* — узып китү, алга чыгу, үтеп китү (чабышта); ◇ **Выскакать ценный приз** — алдан килеп кыйммәтле приз (бүләк) алу.

**ВЫСКА'КИВАТЬ** *несов.* — 1. к. выскакать; 2. к. выскочить.

**ВЫСКА'ЛЬЗЫВАТЬ** *несов.* — к. выскользнуть.

**ВЫ'СКОБЛИТЬ** *сов.* — 1. кырып шомарту, кырып тигезләү; 2. кырып алу, кырып ташлау, кырып бетерү; *выскоблить помарку в рукописи* — кулъязмадагы пычранган урынны кырып алу.

**ВЫСКОЛЬЗА'ТЬ** *несов.* — к. выскользнуть.

**ВЫ'СКОЛЬЗНУТЬ** *сов.* — 1. шуып төшү, шуып төшеп китү, ычкыну, ычкынып китү; *рыба выскользнула из рук* — балык кулымнан ычкынып китте; 2. *перен.* таю, шылу, сызу, (сиздермичә) чыгып китү; *он незаметно выскользнул из комнаты* — ул сиздермичә генә бүлмәдән тайды (чыгып китте).

**ВЫ'СКОЧИТЬ** *сов.* — 1. сикереп чыгу, сикереп төшү; *выскочить из окна* — тәрәзәдән сикереп чыгу; 2. (*выпасть*) төшү,

төшеп китү; 3. *мор.* килеп бәрелү, килеп утыру; *корабль выскочил на мель*—корабль комга килеп утырды; 4. килеп чыгу; *из-за угла выскочила собака* — чаттан эт килеп чыкты; 5. (*неуместно вмешаться*) тыгылу, тыкшыну, урынсызга катнашу.

**ВЫ'СКОЧКА** *м.* и *ж.* *разг.* — выскочка; тыгылучы, үзен күрсәтергә тырышучы.

**ВЫСКРЕБА'ТЬ** *несов. разг.* — к. выскрести.

**ВЫСКРЕБА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — кырып тазартылу.

**ВЫ'СКРЕСТИ** и **ВЫ'СКРЕСТЬ** *сов. разг.* — 1. (*выскоблить*) кырып тазарту; 2. (*выгрести*) көрәп чыгару.

**ВЫ'СЛАТЬ** *сов.* — 1. җибәрү, салу; *выслать посылку почтой* — почта белән посылка җибәрү; *выслать деньги* — акча салу (җибәрү); *выслать лошадей на станцию* — станциягә атлар җибәрү; 2. *офиц.* сөрү, куу; *выслать из города* — шәһәрдән сөрү; 3. *воен. спорт.* сузу, чыгару; *выслать пику вперёд* — сөңгене алга сузу.

**ВЫ'СЛЕДИТЬ** *сов.* — эзенә төшү; *охотник выследил медведя* — аучы аюның эзенә төште.

**ВЫСЛЕ'ЖИВАТЬ** *несов.* — сагалап йөрү, күзәтеп йөрү.

**ВЫСЛЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сагалану, күзәтелү.

**ВЫ'СЛУГА: за выслугу лет** — күп еллар хезмәт иткән өчен.

**ВЫСЛУ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. выслужить.

**ВЫСЛУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — ярарга тырышу, ярарга тырышып ялагайлану, тәлинкә тоту.

**ВЫ'СЛУЖИТЬ** *сов.* — 1. хезмәт итеп ирешү, хезмәт итеп табу, хезмәт итеп алу; *выслужить полную пенсию* — хезмәт итеп тулы пенсия алу; 2. *разг.* хезмәт итү; *выслужить 25 лет* — 25 ел хезмәт итү.

**ВЫ'СЛУЖИТЬСЯ** *сов. разг.* — ялагайланып үз теләгенә ирешү.

**ВЫ'СЛУШАТЬ** *сов.* — тыңлау, тыңлап бетерү.

**ВЫСЛУ'ШИВАТЬ** *несов.* — к. выслушать.

**ВЫСМА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. высмолить.

**ВЫСМА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. высмолиться.

**ВЫСМА'ТРИВАТЬ** *несов.* — 1. к. высмотреть 1; 2. (*искать глазами*) күз белән эзләү; 3. (*выслеживать*) күзәтеп тору; 4. *разг.* (*выглядывать*) карау, карап тору.

**ВЫСМЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. высмеять.

**ВЫСМЕ'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — мыскыл ителү, мәсхәрә ителү.

**ВЫ'СМЕЯТЬ** *сов.* — көлү, мыскыллау, мыскыл итү, мәсхәрәләү, көлкегә калдыру.

**ВЫ'СМОЛИТЬ** *сов.* — сумалалау, сумала сылау.

**ВЫ'СМОЛИТЬСЯ** *сов.* — 1. сумалага буялу, сумалалану; 2. сагызлану, сагызы чыгу; *сук в доске высмолился* — тактадагы ботакның сагызы чыккан.

**ВЫ'СМОРКАТЬ** *сов. разг.* — сеңгереп ташлау.

**ВЫ'СМОРКАТЬСЯ** *сов. разг.* — сеңгерү.

**ВЫ'СМОТРЕТЬ** *сов.* — 1. карап чыгу, җентекләп карап чыгу; *он высмотрел всю выставку* — ул бөтен күргәзмәне җентекләп карап чыкты; 2. карап табу, күзәтеп табу, күз белән эзләп табу; *высмотреть в толпе знакомого* — халык арасыннан танышны карап табу; 3. күзәтеп белү; *высмотреть расположение сил противника* — дошман көчләренең торышын күзәтеп белү. ◇ **Высмотреть глаза** *разг.* — карый-карый күзләрне талдыру.

**ВЫСО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. высунуть.

**ВЫСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. высунуться.

**ВЫСО'КИЙ** — 1. биек, югары, калку, озын; *высокий дом* — биек өй; *высокая местность* — югары (калку) урын; *высокие облака* — югары болытлар; *высокий рост* — озын буй; 2. *перен.* югары, күтәренке; *высокое давление* — югары басым; *высокий процент* — югары процент, күтәренке процент; 3. *перен.* бөек, зур; хөрмәтле, кадерле; *высокое звание* — бөек исем; *высокая честь* — зур хөрмәт; *высокий гость* — хөрмәтле кунак; 4. ихтирамлы, хөрмәтле; *высокие договаривающиеся стороны* — ихтирамлы килешүче яклар; 5. *перен.* иң яхшы; *высокий сорт товаров* — товарларның иң яхшы сорты; 6. *перен.* тирән, тирән эчтәлекле, бик әһәмиятле; бөек; *высокие мысли* — тирән эчтәлекле фикерләр; *высокие побуждения* — бөек (тирән) уйлар (теләкләр); 7. *перен.* (*о звуках*) нечкә, югары; 8. *перен. лит.* купшы, тантаналы; *высокий стиль* — купшы стиль, тантаналы стиль ◇ **Высокий лоб** — киң маңгай. **Высокая грудь** — калку күкрәк. **Быть высокого мнения о ... — ...** турында яхшы фикердә булу. **Быть высокого мнения о себе** — үзеңне зурга кую. **Не высокого полёта птица** — әллә кем түгел. **Высокого полёта человек** — зур дәрәҗәле кеше. **Жеребец высоких кровей** — яхшы нәселле айгыр.

**ВЫСОКО', ВЫСО'КО** — 1. *нареч.* югары; *высоко держать знамя* — байракны югары тоту; 2. *безл. в знач. сказ.* биек; ерак; *до неба высоко* — күккә ерак; *опустите ниже, так мне высоко* — түбәнрәк төшерегез, болай миңа биек.

**ВЫСОКОВО'ЛЬТНЫЙ** *тех.* — югары вольтлы.

**ВЫСОКОГО'РНЫЙ** — биек таудагы, биек тау...-ы; *высокогорные луга* — биек тау болыннары.

**ВЫСОКОДОХО'ДНЫЙ** — күп доходлы, зур табышлы, күп доход бирә торган; *высокодоходное колхозное хозяйство* — күп доход бирә торган колхоз хуҗалыгы.

**ВЫСОКОИДЕ'ЙНЫЙ** — югары идеяле; *высокоидейное произведение* — югары идеяле әсәр.

**ВЫСОКОКА'ЧЕСТВЕННЫЙ** — югары сыйфатлы, иң яхшы сыйфатлы.

**ВЫСОКОКВАЛИФИЦИ'РОВАННЫЙ** — югары квалификацияле, зур тәҗрибәле.

**ВЫСОКОКУЛЬТУ'РНЫЙ** — югары культуралы.

**ВЫСОКОМЕ'РИЕ** *ср. мн.* нет — тәкәбберлек, һавалылык, эрелек, борын күтәрү.

**ВЫСОКОМЕ'РНИЧАТЬ** *несов. разг.* — үзен эре тоту, тәкәбберләнү, борын күтәрү.

**ВЫСОКОМЕ'РНЫЙ** — тәкәббер, һавалы.

**ВЫСОКОМЕХАНИЗИ'РОВАННЫЙ** — югары дәрәҗәдә механикалаштырылган; *высокомеханизированное социалистическое сельское хозяйство* — югары дәрәҗәдә механикалаштырылган социалистик авыл хуҗалыгы.

**ВЫСОКООБРАЗО'ВАННЫЙ** — бик зур белемле, зур белемле.

**ВЫСОКООПЛА'ЧИВАЕМЫЙ** — 1. югары дәрәҗәдә түләнә торган, күп түләнә торган; *высокооплачиваемый труд* — югары дәрәҗәдә түләнә торган хезмәт; 2. югары хезмәт хакы ала торган; *высокооплачиваемый работник* — югары хезмәт хакы ала торган работник.

**ВЫСОКОПА'РНО** *нареч.* — күпертеп; *выражаться высокопарно* — күпертеп сөйләү.

**ВЫСОКОПА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — кабартылганлык, күпертелгәнлек.

**ВЫСОКОПА'РНЫЙ** — кабарынкы, күперенке; *высокопарный стиль* — күперенке стиль.

**ВЫСОКОПЛОДОРО'ДНЫЙ** — югары (дәрәҗәдә) уңдырышлы.

**ВЫСОКОПОСТА'ВЛЕННЫЙ** *устар.* — югары дәрәҗәдәге, югары урындагы.

**ВЫСОКОПОЧТЕ'ННЫЙ** *устар.* — хөрмәтле, кадерле.

**ВЫСОКОПРЕВОСХОДИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. офиц. дипл.* — галиҗәнап.

**ВЫСОКОПРО'БНЫЙ** — 1. югары пробалы (алтын-көмеш турында); 2. югары сыйфатлы, яхшы сыйфатлы; *высокопробная сталь* — югары сыйфатлы корыч.

**ВЫСОКОПРОДУКТИ'ВНЫЙ** — югары (дәрәҗәдә) продуктлы, күп продукт бирә торган.

**ВЫСОКОПРОИЗВОДИ'ТЕЛЬНЫЙ** — югары дәрәҗәдә житештерүчән; *высокопроизводительный труд* — югары дәрәҗәдә житештерүчән хезмәт.

**ВЫСОКОРО'СЛЫЙ** — озын буйлы.

**ВЫСОКО'СНЫЙ** — к. високосный.

**ВЫСОКОСО'РТНЫЙ** — югары сортлы.

**ВЫСОКОТАЛА'НТЛИВЫЙ** — бик талантлы, югары дәрәҗәдә талантлы.

**ВЫСОКОУВАЖА'ЕМЫЙ** — хөрмәтле, мөхтәрәм; *высокоуважаемый Иван Иванович!* — хөрмәтле Иван Иванович!

**ВЫСОКОУДО'ЙНЫЙ** — күп сөтле, күп сөт бирә торган; *высокоудойная корова* — күп сөт бирә торган сыер.

**ВЫСОКОУ'МНЫЙ** *ирон.* — акыллы баш (акыллы булып күренергә тырышучы).

**ВЫСОКОУРОЖА'ЙНЫЙ** — күп уңыш бирә торган.

**ВЫСОКОЦЕ'ННЫЙ** — бик кыйммәтле.

**ВЫСОКОЧТИ'МЫЙ** *устар.* — бик хөрмәтле, бик ихтирамлы, бик хөрмәт итела торган.

**ВЫ'СОЛИТЬ** *сов. разг.* — тозлау, тоз сеңдерү.

**ВЫ'СОЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — тозлану, тоз сеңү.

**ГАЙКОРЕ'З** *м. тех.*— гайка сырлагыч, гайкорез.

**ГАК:** **с гаком** —артыгы белән; артык; *три кило с гаком* — артыгы белән өч кило; *три часа с гаком* — өч сәгатьтән артык.

**ГАЛА'КТИКА** *ж. астр.*— 1. Галактика (Киек Каз Юлы дип йөртелә торган йолдызлар системасы); 2. галактика (Киек Каз Юлы системасыннан читтәге йолдызлар системалары).

**ГАЛАНТЕРЕ'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг. фам. ирон.*— тәкәллефлелек.

**ГАЛАНТЕРЕ'ЙНЫЙ** — 1. галантерея ...-ы; вак товарлар ...-ы; *галантерейный магазин* — галантерея магазины; 2. *разг. фам. ирон.* тәкәллефле; *галантерейное обращение* — тәкәллефле мөгамәлә.

**ГАЛАНТЕРЕ'ЙЩИК** *м.*— галантерейщик (галантерея товарлары сатучы).

**ГАЛАНТЕРЕ'Я** *ж. мн.* нет — галантерея товарлары, вак товарлар (мәсәлән, сәдәп, каптырма, сабын һ. б.).

**ГАЛА'НТНО** *нареч.* — зур тәкәллеф белән, бик зур нәзакәт күрсәтеп.

**ГАЛА'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *устар.* — артык дәрәҗәдә нәзакәтлелек, артык тәкәллефлелек.

**ГАЛА'НТНЫЙ** *устар.* — артык нәзакәтле, артык тәкәллефле.

**ГАЛДЁЖ** *м. мн.* нет — шау-шу, чыр-чу.

**ГАЛДЕ'ТЬ** *несов. разг. фам.*— шау килү, чыр килү, чыр-чу килү.

**ГАЛЕ'РА** *ж. истор.* — галера (күп ишкәкле борынгы көймә). ◇ **Сослать на галеры** — галерага җибәрү (электә Көнбатыш Европада җинаятьчеләрне галерада эшләү өчен ишкәкче итеп җибәрә торган булганнар).

**ГАЛЕРЕ'Я** *ж.*— 1. галерея (а. бинаның аерым өлешләрен тоташтыру өчен эшләнгән коридор, шулай ук бина буйлап эшләнгән озын балкон; б. крепостьның, хәрби корылманың яки шахтаның аерым кисәкләрен тоташтыра торган җир асты юлы; в. театрның иң югары ярусы; г. к. картинная галерея); 2. *перен.* галерея, тезмә, төркем; *галерея литературных типов* — әдәби типлар галереясы (тезмәсе). ◇ **Картинная галерея** — картиналар галереясы (халыкка күрсәтү өчен картиналар эленеп куела торган махсус бина, музей).

**ГАЛЁРКА** *ж. разг. фам.* — 1. галёрка (театрның иң югары ярусы); 2. *перен.* галёркадагы тамашачылар. ◇ **На галёрке** *перен. разг. шутл.*— иң артта.

**ГАЛЕ'ТА** *ж.* — 1. галета (печеньенең бер төре); 2. киптерелгән төче күмәч.

**ГАЛИМАТЬЯ'** *ж. мн.* нет, *разг.*— буш сүз, мәгънәсез сүз, юк-бар сүз, сафсата.

**ГАЛИФЕ'** *нескл. ср.* — галифе (гаскәри чалбарның бер төре).

**ГА'ЛКА** *ж. зоол.*— чәүкә.

**ГАЛЛЕРЕ'Я** *ж.*— *к.* галерея.

**ГАЛЛИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *лингв. лит.*— галлицизм (француз теленнән алынган сүз яки әйтелмә; француз теле үрнәгендә төзелгән әйтелмә).

**ГАЛЛОМА'Н** *м.*— галломан (француз телен, гореф-гадәтләрен һ. б. исе китеп яратучы кеше).

**ГАЛЛОМА'НИЯ** *ж. мн.* нет — галломания (француз телен, гореф-гадәтләрен һ. б. исе китеп ярату).

**ГАЛЛОФО'Б** *м.*— галлофоб (француз теленә, гореф-гадәтләренә һ. б. нәфрәт белән караучы кеше).

**ГАЛЛОФО'БИЯ** *ж. мн.* нет — галлофобия (француз теленә, гореф-гадәтләренә һ. б. нәфрәт белән карау).

**ГА'ЛЛЫ** I *мн.* (*ед.* галл) — 1. *истор.* галлар (хәзерге Франция җирендә яшәгән борынгы кельт кабиләсе); 2. *устар.* французлар.

**ГА'ЛЛЫ** II — орылар (үсемлекләр өстенә чыга торган каты кабырчыклар, кутырлар).

**ГА'ЛЛЬСКИЙ** — галлар ...-ы; *галльская война* — галлар сугышы.

**ГАЛЛЮЦИНА'ЦИЯ** *ж. мед.* — галлюцинация (сизү, тою, күрү, ишетү органнарының алдавы, мәсәлән, юк нәрсәне күрү яки юк тавышны ишетү).

**ГАЛЛЮЦИНИ'РОВАТЬ** *несов.* — галлюцинациядән җәфалану, галлюцинация белән җәфалану.

**ГАЛО'П** *м. мн.* нет — 1. (*о лошади*) сикертеп чабу; 2. (*танец*) галоп.

**ГАЛОПИ'РОВАТЬ** *несов.* — сикертеп чабу (атта).

**ГАЛО'ПОМ** *нареч.* — 1. (*вскачь*) сикертеп чабып, чаптырып; 2. *перен.* (*очень быстро*) бик тиз; өстән-өстән генә.

**ГА'ЛОЧИЙ** — чәүкә ...-ы; *галочье гнездо* — чәүкә оясы.

**ГАЛО'ШИ** *мн.* — галош. ◇ **Сесть в галошу** — төпсез чанага утыру (алдану). **Посадить в галошу** — төпсез чанага утырту, кәкре каенга терәтү.

**ГА'ЛСТУК** *м.* — галстук.

**ГА'ЛСТУЧНЫЙ** — галстук ...-ы; *галстучное производство* — галстук производствосы.

**ГА'ЛСТУШНИК** *м. зоол.* — кара бүксә (кош).

**ГАЛУ'Н** *м.* — ука.

**ГАЛУ'ШКИ** *мн.* (*ед.* галушка) — чумар, Украина чумары.

**ГАЛЧО'НОК** *м.* (*мн.* галчата) — чәүкә баласы.

**ГАЛЬВАНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — гальванизация (электр тогын техникада яки медицинада куллану).

**ГАЛЬВАНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. гальванизацияләү, гальванизация ясау (а. медицина максаты белән электр тогы куллану; б. электролиз ярдәмендә нинди дә булса предметның өстен металл белән каплау); 2. *перен.* терелтү, хәрәкәткә китерү (ясалма рәвештә); *гальванизировать сердце лягушки* — бакаиың йөрәген терелтү (электр ярдәме белән хәрәкәткә китерү).

**ГАЛЬВАНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — гальванизацияләнү (берәр нәрсә аша гальваник ток үткәрелү).

**ГА'ЛЬКА** *ж. мн.* нет — чуерташ.

**ГАЛЬЮ'Н** *м.* — бәдрәф (корабльдә).

**ГАМ** *м. мн.* нет — шау-шу, тавыш.

**ГАМА'К** *м.* — гамак (үреп ясалган асылмалы ятак).

**ГАМА'ШИ** *мн.* (ед. гамаша) — гамаш (бәйләп эшләнгән оек кунычы).

**ГАНГРЕ'НА** *ж. мн.* нет, *мед.* — гангрена (әгъзаларда яки тәннең берәр урынында тереклек процессы тукталу һәм тәннең кара янып черүе).

**ГАНГРЕНО'ЗНЫЙ** *мед.* — гангрена ...-ы; *гангренозный процесс* — гангрена процессы.

**ГА'НГСТЕР** *м.* — гангстер (АКШта бандитлар шайкасында катнашучы; АКШның монополистлары һәм боссларьі үзләренең пычрак, җинаятьчел эшләрен тормышка ашыруда гангстерлардан файдаланалар). ◇ **Гангстеры пера** *перен.* — сатлык буржуаз журналистлар, язучылар.

**ГАНГСТЕРИ'ЗМ** *м. мн.* нет — гангстерлык, бандитлык (АКШта монополистик капитал белән бәйләнгән һәм киң күләмдә таралган талау).

**ГАОЛЯ'Н** *м. мн.* нет, *бот.* — гаолян (тарының бер төре).

**ГАРА'Ж** *м.* — гараж (автомашиналарны, мотоциклларны саклау, төзәтү, көйләү урыны).

**ГАРА'НТ** *м.* — гарант, гарантия бирүче, ышанычлык бирүче.

**ГАРАНТИ'ЙНЫЙ** — гарантия ...-ы, гарантияле, ышанычлы; *гарантийный договор* — гарантия договоры.

**ГАРАНТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. гарантияләү; гарантия бирү, ышаныч бирү; *гарантировать качество товара* — товарның сыйфатын гарантияләү; 2. тәэмин итү, саклау; *прививки гарантируют от тяжёлых заболеваний* — прививкалар каты авырулардан саклый.

**ГАРАНТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. гарантияләнү, гарантия бирелү, ышаныч бирелү; 2. тәэмин ителү.

**ГАРА'НТИЯ** *ж.* — гарантия, ышаныч; *прививка оспы — гарантия от заболевания ею* — чәчәк салу — чәчәк авыруыннан гарантия; *у меня нет никакой гарантии* — минем бернинди ышанычым юк.

**ГАРДЕРО'Б** *м.* — гардероб (1. кием шкафы; 2. учреждениеләргә, театрларга һ. б. килүче кешеләрнең кием-салымын саклау бүлмәсе; 3. бер кешенең яки бер семьяның барлык кием-салымы).

**ГАРДЕРО'БНАЯ** *ж. в знач. сущ.* — гардероб бүлмәсе (учреждениеләргә, театрларга һ. б. килүче кешеләрнең кием-салымын саклау бүлмәсе).

**ГАРДЕРО'БНЫЙ** — гардероб ...-ы; *гардеробный ключ* — гардероб ачкычы.

**ГАРДЕРО'БЩИК** *м.*, **ГАРДЕРО'БЩИЦА** *ж.* — гардеробта эшләүче.

**ГАРДИ'НА** *ж.* — гардина (тәрәзәне тулысынча каплый торган пәрдә).

**ГАРЕ'М** *м.* — гарем, хәрәм (1. күп хатын алу гадәте булган Көнчыгыш илләрендә бай ирнең хатыннары; 2. өйнең шул хатыннар өчен булган яртысы).

**ГА'РКАТЬ** *несов. простореч.* — җикерү, җикеренү, акыру, акырыну, җикереп кычкыру, кычкырыну.

**ГА'РКНУТЬ** *сов.* и *однокр. простореч.* — кычкырып кую.

**ГАРМО'НИКА** *ж.* — гармонь.

**ГАРМОНИ'РОВАТЬ** *несов.* — ярашып тору, килешеп тору; *его слова гармонируют с его поступками* — аның сүзләре эшләгән эшләре белән ярашып тора.

**ГАРМОНИ'СТ** *м.* — 1. гармоньчы; 2. гармониягә оста композитор.

**ГАРМО'НИУМ** *м. устар.* — фисгармония (музыка коралы).

**ГАРМОНИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *муз.* гармоник; *гармонический стиль* — гармоник стиль; 2. гармонияле, аһәнле; *гармонический голос* — гармонияле (аһәнле) тавыш; 3. *науч.* төзек, тәртипле; *гармонические колебания* — тәртипле тибрәнүләр.

**ГАРМОНИ'ЧНО** *нареч.* — ярaштырып, ярашып.

**ГАРМОНИ'ЧНОСТЬ** *ж.* — гармониялелек.

аһәңлелек; төзеклелек, ярашканлык, бөтен яктан килешкәнлек.

**ГАРМОНИ'ЧНЫЙ** — к. гармонический 2, 3.

**ГАРМО'НИЯ** *ж.* — 1. гармония (музыка теориясенең бер бүлеге); 2. (*благозвучие*) аһәң, аһәңлелек, ягымлылык, төзеклелек; 3. *перен.* үзара ярашу, ярашканлык, (үзара) туры килүчәнлек, ятышлылык, килешлелек; *гармония красок* — буяуларның үзара ярашулары.

**ГАРМО'ННЫЙ** — гармонь ...ы; *гармонный мастер* — гармонь остасы.

**ГАРМО'НЬ** *ж. разг.* — гармонь.

**ГА'РНЕЦ** *м. устар.* — гарнец (элекке Россиядә 3,28 литр сыешлы үлчәү берәмлеге).

**ГАРНИЗО'Н** *м. воен.* — гарнизон (бер шәһәрдә яки крепостьта тора торган гаскәрләр).

**ГАРНИЗО'ННЫЙ** — гарнизон ...-ы; *гарнизонная служба* — гарнизон хезмәте.

**ГАРНИ'Р** *м. кулин.* — гарнир (иттән яки балыктан әзерләнгән ашка кушып бирелә торган бәрәңге, яшелчә, ботка һ. б.).

**ГАРНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — гарнирлау, гарнир салу (ашамлыкка төрле тәм керткеч әйберләр салу).

**ГАРНИТУ'Р** *м.*, **ГАРНИТУ'РА** *ж.* — гарнитур (берәр нәрсәгә хезмәт итә торган әйберләрнең тулы комплекты).

**ГА'РНЦЕВЫЙ** *устар.* — гарнец ...-ы; *гарнцевая система* — гарнец системасы. ◇ **Гарнцевый сбор** — кәрәк оны (тегермән тарткан өчен алына торган он).

**ГА'РНЫЙ** — ягу өчен тотыла торган; яндыру ...-ы; *гарное масло* — яндыру мае.

**ГАРПУ'Н** *м.* — гарпун (1. *мор.* эре диңгез хайваннарын аулаганда бауга бәйләп ыргытыла торган ыргаклы сөңге; 2. печән бушата торган тимер таяк; 3. ике стенаны беркетә торган тимер атлама).

**ГАРСО'Н** *м.* — гарсон (1. Франциядә — ресторанда яки кафеда официант; 2. *загр.* гостиницада йомышка йөри торган малай).

**ГА'РУС** *м. мн.* нет, *текст.* — гәрес (1. тупасрак йон жеп; 2. йон материягә охшаган мамык материя төре).

**ГА'РУСНЫЙ** — гәрес ...; *гарусный шарф* — гәрес шарф (гәрестән бәйләнгән шарф).

**ГАРЦЕВА'ТЬ, ГАРЦОВА'ТЬ** *несов.* — ат өстендә оста йөрү, атны биетеп бару.

**ГАРЬ** *ж. мн.* нет — 1. көек; *пахнет гарью* — көек исе килә; 2. (*пожарище в лесу*) янык; 3. ташкүмер көле; *посыпать дорожку гарью* — юлга ташкүмер көле сибү.

**ГАСИ'ЛЬНИК** *м. тех.* — сүндергеч (фонарь, шәм кебекләрне сүндерү өчен эшләнгән калпак).

**ГАСИ'ЛЬНЫЙ** — сүндерә торган.

**ГАСИ'ТЕЛЬ** *м.* — 1. *тех.* сүндергеч (утны); 2. *перен.* сүндерүче, томалаучы (мәсәлән, мәгариф эшен).

**ГАСИ'ТЬ** *несов.* — 1. сүндерү; 2. каплау, түләп бетерү; *гасить старые долги* — иске бурычларны каплау (түләп бетерү); *гасить почтовую марку* — почта маркасын гамәлдән чыгару (өстенә печать басып); 3. *перен.* томалау, буу, басу; *гасить инициативу* — инициативаны буу.

**ГАСИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. сүндерелү; 2. каплану, түләнү.

**ГА'СНУТЬ** *несов.* — 1. сүнү; 2. *перен.* сүнә бару, бетә бару, көчсезләнә бару, хәлсезләнә бару; *силы гаснут* — көч бетә бара; *надежды гаснут* — өметләр сүнә (бетә) бара.

**ГАСТРИ'Т** *м. мед.* — гастрит (ашказаны авыруы).

**ГАСТРИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — гастрит ...-ы; *гастрическая лихорадка* — гастрит бизгәге.

**ГАСТРОЛЁР** *м.*, **ГАСТРОЛЁРША** *ж.* — гастролёр (1. *театр.* гастрольгә килгән артист; 2. *перен. разг. шутл.* нинди дә булса эшне очраклы һәм вакытлы рәвештә генә үтәүче; эштән эшкә күчеп йөрүче).

**ГАСТРО'ЛИ** *мн.* (*ед.* гастроль) — гастроль (читтән килгән артистларның спектакль куюлары һәм чыгышлары).

**ГАСТРО'ЛЬНЫЙ** — гастроль ...-ы; гастрольгә ... ; *гастрольная труппа* — гастроль труппасы; *гастрольные поездки* — гастрольгә чыгулар.

**ГАСТРОНО'М** *м.* — гастроном (1. нәфис һәм тәмле ашамлыклар һәвәскәре һәм аларны белүче; 2. гастрономия магазины).

**ГАСТРОНОМИ'ЧЕСКИЙ** — гастрономия ...-ы; *гастрономический магазин* — гастрономия магазины.

**ГАСТРОНО'МИЯ** *ж. мн.* нет — гастрономия (1. кулинария осталыгының нечкәлекләрен белү; 2. җиренә җиткереп хәзерләнгән ашамлык товарларының гомуми исеме).

**ГАТИ'ТЬ** *несов.* — гать җәю (сазлык аркылы үтә торган юлга чыбык-чабык, таш, салам һ. б. җәю).

**ГАТИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — гать җәелү.

**ГАТЬ** *ж.* — гать (баткак урыннарда таш, бүрәнә, чыбык һ. б. җәелгән юл).

**ГА'УБИЦА** *ж. воен.* — гаубица (артиллерия оруднесе).

**ГА'УБИЧНЫЙ** *воен.* — гаубица ...-ы; *гаубичный огонь* — гаубица уты.

**ГАУПТВА'ХТА** *ж. воен.* — гауптвахта (гаепләнгән гаскәриләрне ябу урыны).

**ГАШИ'Ш** *м. мн.* нет — гашиш, нәшә (һинд киндере орлыгыннан алына торган исерткеч матдә).

**ГА'ЩИВАТЬ** *многокр. устар.* — кунак булгалау, кунакка килгәләү.

**ГВАЛТ** *м. мн.* нет, *разг.* — кычкырыш, тавыш, шау-шу, гауга, чыр-чу.

**ГВАРДЕ'ЕЦ** *м.* — гвардеец, гвардиячe (гвардиядә хезмәт итүче яки хезмәт иткән кеше).

**ГВАРДЕ'ЙСКИЙ** — гвардия ...-ы; *гвардейский полк* — гвардия полкы.

**ГВА'РДИЯ** *ж. мн.* нет — гвардия (1. *истор.* электә патшаның яки полководецның сакчы гаскәре; соңыннан — сайланып алынган иң яхшы гаскәрләр. 2. СССР да 1941—1945 елларда Бөек Ватан сугышында аеруча батырлык күрсәткән частьларга, хәрби бер-

ләшмәләргә, корабльләргә бирелгән исем). ◇ **Красная гвардия** — Кызыл гвардия (1917 елда революцион эшчеләрнең кораллы отрядлары). **Старая гвардия** — карт гвардия (берәр өлкәдә сыналган, тәҗрибәле эшлеклеләр). **Белая гвардия** — ак гвардия (гражданнар сугышы чорында контрреволюцион гаскәрләр).

**ГВОЗДА'РНЫЙ** — кадак ясау...-ы; *гвоздарный цех* — кадак ясау цехы.

**ГВОЗДА'РНЯ** *ж.*— кадак мастерское.

**ГВОЗДА'РЬ** *м.*— кадакчы, кадак ясаучы.

**ГВОЗДЕВО'Й**— кадак ...-ы; *гвоздевой материал* — кадак материалы (кадак эшләүгә китә торган материал).

**ГВО'ЗДИК** *м.*— кечкенә кадак.

**ГВОЗДИ'КА** *ж.*— 1. *бот.* канәфер чәчәк; 2. *только ед.* (*пряность*) канәфер.

**ГВОЗДИ'ЛЬНЫЙ** — кадак ясый торган, кадак ясау ...-ы; *гвоздильная машина* — кадак ясау машинасы.

**ГВОЗДИ'ЛЬЩИК** *м.* — кадакчы (кадак ясау производствосында эшләүче).

**ГВОЗДИ'ТЬ** *несов.* — 1. (*вколачивать*) кадаклау, кагып кертү, кагу; 2. (*бить, колотить*) сугу, тукмау, кыйнау; 3. *перен.* (*бранить*) орышу, тиргәү, сугү, ачулану; 4. *перен.* туку, колакка туку (бер үк сүзне кат-кат әйтү).

**ГВОЗДИ'ЧНЫЙ** — канәфер ...-ы; канәфердән әзерләнгән; *гвоздичное масло* — канәфер мае.

**ГВОЗДОДЁР** *м.*— кадак суыргыч, келәшчә.

**ГВОЗДЬ** *м.*—1. кадак; *вешать на гвоздь*— кадакка элеп кую; 2. *перен.* үзәк, нигез, иң әһәмиятле як; *гвоздь вопроса* — мәсьәләнең үзәге, мәсьәләнең иң әһәмиятле ягы. ◇ **И никаких гвоздей** — әйткән-беткән, артык сөйләшеп торасы да юк.

**ГВОЗДЯНО'Й** — кадак ...-ы; *гвоздяная шляпка* — кадак башы.

**ГДЕ** I *нареч.*— 1. кайда; *где ты был?* — син кайда булдың? 2. кайда да булса, берәр җирдә; *не видали ли где моей книги?*— минем китабымны кайда да булса күрмәдегезме? 3. бер очракта ... икенче очракта ...; бер урында ... икенче урында ...; *где можно, а где нельзя* — бер урында ярый, икенче урында ярамый; 4. кая инде, кая ул; *где старому человеку осилить такую работу!* — кая инде карт кешегә мондый эшне җиңеп чыгу! *где уж нам в таких вещах разбираться!* — кая инде безгә мондый мәсьәләләрне аңлау! ◇ **Где бы** (*с инфинитивом*) — ...-сы урында; *где бы ему работать, а он разговорами занимается* — эшлисе урында ул сөйләшеп утыра.

**ГДЕ** II *союз* — ...-ган; *в странах, где победил народный фронт* — халык фронты җиңгән илләрдә.

**ГДЕ-ГДЕ** *нареч.* — анда-монда, ара-тирә; *где-где только светятся узкие окна* — анда-монда гына тар тәрәзәләрдән яктылык күренә.

**ГДЕ-ЛИ'БО** *нареч.*— кинди дә булса, кайда да булса; *продукты хранятся где-либо в холодном помещении* — азыклар нинди дә булса бер салкын бинада саклыналар.

**ГДЕ-НИБУ'ДЬ** *нареч.*— кайда да булса, нинди дә булса бер җирдә; *где-нибудь пообедаем* — кайда да булса ашап алырбыз.

**ГДЕ'-ТО** *нареч.* — кайдадыр, кайдадыр шунда.

**ГЕБРАИ'СТ** *м. филол.*— гебраистика белгече.

**ГЕБРАИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *филол.*—гебраистика (борынгы еврей теле һәм язуы турындагы фән).

**ГЕГЕЛЬЯ'НЕЦ** *м. филос.*— гегельче (Гегель философиясен яклаучы).

**ГЕГЕЛЬЯ'НСТВО** *ср. мн.* нет, *филос.* — гегельчелек (Гегель философиясе нигезендә барлыкка килгән идеалистик философик юнәлеш).

**ГЕГЕМО'Н** *м.*— гегемон, җитәкче; *пролетариат — гегемон революции* — пролетариат — революциянең гегемоны.

**ГЕГЕМО'НИЯ** *ж. мн.* нет — гегемония (җитәкчелек итү; нинди дә булса берәр сыйныфның яки дәүләтнең икенче сыйныфларга яки дәүләтләргә карата җитәкчелек роле); *гегемония пролетариата в революции* — революциядә пролетариат гегемониясе.

**ГЕ'ДЖРА** *ж.*— һиҗри (мөселман илләрендә ел исәбен йөртү системасы; безнең эраның 622 елыннан башлана).

**ГЕДОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.*— гедонизм (этикада тормышның төп максаты кәеф-сафа чигүдән гыйбарәт дип раслаучы юнәлеш).

**ГЕЕ'ННА** *ж. церк.*— җәһәннәм, тамуг.

**ГЕЙ!** *межд.*— әй!

**ГЕ'ЙЗЕР** *м. геол.*— гейзер (әледән-әле минераллы кайнар су атып тора торган чишмә).

**ГЕ'ЙША** *ж.*— гейша (Япониядә күңел ачу урыннарында профессиональ җырчы-биюче хатын-кыз).

**ГЕКАТО'МБА** *ж.*— гекатомба (1. *рел.* борынгы грекларда күп корбан чалу; 2. *перен.* үлеш, күп кешеләрнең мәгънәсезгә һәлак булуы яки үтерелүе).

**ГЕКЗА'МЕТР** *м. лит.*— гекзаметр (алты стопалы шигырь төре).

**ГЕКТА'Р** *м.*— гектар (җир үлчәү берәмлеге; 10 000 кв. метрга тигез).

**ГЕКТО'ГРАФ** *м. тех.*— гектограф (кулъязманы күбәйтеп басу приборы).

**ГЕКТОГРАФИ'РОВАТЬ** *несов.* — гектографта басу.

**ГЕКТОГРАФИ'РОВАТЬСЯ** *несов.страд.*— гектографта басылу.

**ГЕКТОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — 1. гектографта басылган; *гектографическая печать* — гектографта басылган матбугат; 2. гектограф ...-ы; *гектографические чернила* — гектограф карасы.

**ГЕКТОЛИ'ТР** *м.*— гектолитр (100 литр).

**ГЕКТОМЕ'ТР** *м.*— гектометр (100 метр).

**ГЕЛЕ'РТЕР** *м.*— гелертер (формаль яктан галим булып исәпләнеп тә үзе ижат итмәүче, тормыштан, практик эштән һәм алдынгы фәннән аерылган кеше; хәрефкә табынучы, хәрефкә ябышып ятучы).

**ГЕЛЕ'РТЕРСКИЙ** — гелертерларча...; *гелертерское изложение предмета* — предметны гелертерларча аңлату (тасвирлау).

**ГЕЛЕ'РТЕРСТВО** *ср. мн.* нет—гелертерлык.

**ГЕ'ЛИЙ** *м. мн.* нет, *хим.*— гелий (химик элемент, бик җиңел газ).

**ГЕЛИКОПТЕ'Р** *м.*— геликоптер (һавадан авыррак очу аппараты; пропеллеры горизонталь урнашкан булу сәбәпле, геликоптер җир өстеннән йөгереп бармыйча туптуры һавага күтәрелеп китә ала, җиргә төшеп җитмичә һавада „асылынып" тора ала, теләсә нинди почмак ясап төшә, горизонталь яки авыш юнәлештә дә оча, ләкин хәзерге самолёттан акрынрак оча).

**ГЕЛИО'ГРАФ** *м.*— гелиограф (1. *воен.* армиядә кояш нурлары ярдәмендә ерак арадан үзара хәбәрләшү өчен кулланыла торган оптик прибор; 2. *тех.* кояш балкышының күпме дәвам итүен яза торган прибор; 3. *астр.* Кояшның рәсемен төшереп алу өчен кулланыла торган телескоп).

**ГЕ'ЛИОС** *м.*— гелиос (борынгы грек мифологиясендә Кояш алласы).

**ГЕЛИОТЕ'ХНИКА** *ж. физ.*— гелиотехника (техниканың промышленность һәм көнкүреш өчен кояш энергиясеннән файдалану эше белән шөгыльләнә торган бүлеге).

**ГЕЛИОЦЕНТРИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *астр.*— гелиоцентризм (Кояш—үзәк, Җир һәм башка планеталар аның тирәсендә һәм, шуның белән бергә, үз күчәрләре тирәсендә әйләнәләр дип раслый торган теория).

**ГЕЛИОЦЕНТРИ'ЧЕСКИЙ** *астр.*— гелиоцентрик; *гелиоцентрическая система* — гелиоцентрик система.

**ГЕ'ЛЛЕР** *м.*—геллер (Чехословакиядә вак акча; кронаның $^1/_{100}$ өлешенә тигез).

**ГЕМОГЛОБИ'Н** *м. биол.* — гемоглобин (канның кызыл шарчыклары составында булып, аңа кызыл төс бирә һәм тәннең бөтен өлешләрен кислород белән тәэмин итә торган матдә).

**ГЕМОРРО'Й** *м. мед.*— геморрой (туры эчәк авыруы).

**ГЕМОРРО'ЙНЫЙ** *мед.*— геморрой ...-ы; *геморройная кровь*— геморрой каны.

**ГЕМОТЕРАПИ'Я** *ж. мед.*— гемотерапия, кан белән дәвалау (бигрәк тә тәнгә кан җибәрү юлы белән).

**ГЕМОФИЛИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.*— гемофилия, күп кан агучанлык (нәселдән килә торган авыру).

**ГЕНЕАЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — генеалогия ...-ы; генеалогик; *генеалогическая таблица* — генеалогия таблицасы; *генеалогическая классификация языков* — телләрнең генеалогик классификациясе. ◇ **Генеалогическое дерево** — нәсел агачы, шәҗәрә.

**ГЕНЕАЛО'ГИЯ** *ж.*— 1. генеалогия (а. тарихның нәсел һәм ыруларны тикшерә торган бүлеге; б. хайваннарның яки үсемлекләрнең килеп чыгуы турындагы мәгълүматлар); 2. (*родословная, история рода*) нәсел тарихы, ыру тарихы, шәҗәрә.

**ГЕ'НЕЗИС** *м. биол., филос.*—генезис (1. килеп чыгу, барлыкка килү; 2. барлыкка килү моменты һәм үсеш процессы).

**ГЕНЕРА'Л** *м.*— генерал (югары хәрби звание).

**ГЕНЕРА'Л-ГУБЕРНА'ТОР** *м.*— генерал-губернатор (буржуаз илләрдә һәм патша Россиясендә губерна, край, колония начальнигы).

**ГЕНЕРАЛИЗА'ЦИЯ** *ж.*— 1. генерализация, гомумиләштерү (аерым күренешне нинди дә булса гомуми принципка буйсындыру); 2. *мед.* генерализация, таралу, җәелү (авыру процессының бөтен тәнгә таралуы).

**ГЕНЕРАЛИЗИ'РОВАТЬ** *несов.* и *сов.* — генерализацияләү, гомумиләштерү (аерым күренешне нинди дә булса гомуми принципка буйсындыру).

**ГЕНЕРАЛИ'ССИМУС** *м. воен.*— генералиссимус (иң югары хәрби звание).

**ГЕНЕРАЛИТЕ'Т** *м. собир.*— генералитет (генераллар, армиянең югары командирлар составы).

**ГЕНЕРА'ЛЬНЫЙ** — генеральный; төп, баш, хәлиткеч; *генеральный секретарь* — генеральный секретарь; *генеральный план*— төп план; *генеральное сражение* — хәлиткеч сугыш. ◇ **Генеральная репетиция** — соңгы репетиция.

**ГЕНЕРА'ЛЬСТВОВАТЬ** *несов.*— 1. (*быть генералом*) генераллык итү; 2. *перен.* (*держать себя властно*) үзен эре тоту.

**ГЕНЕРА'ЛЬША** *ж. разг.*— генерал хатыны.

**ГЕНЕРАТИ'ВНЫЙ** — генератив, женси; *генеративные клетки* — генератив (женси) күзәнәкләр.

**ГЕНЕРА'ТОР** *м. тех.*— 1. генератор, динамомашина (механик энергияне электр энергиясенә әвереллерә торган машина); 2. к. газогенератор.

**ГЕНЕРА'ТОРНЫЙ** *тех.*— генератор...-ы; *генераторный газ* — генератор газы.

**ГЕНЕРИ'РОВАТЬ** *несов., радио* —шаулау, чыелдау (антеннада киләксез электромагнит тибрәнүләр булу сәбәпле радиоалгычның шаулавы).

**ГЕНЕ'ТИКА** *ж. биол.*— генетика (организмнарның нәселдәнлеген һәм аның үзгәрүчәнлеген өйрәнә торган фән).

**ГЕНЕТИ'ЧЕСКИЙ**—генетик; генетика ...-ы; *генетический метод* — генетик метод; *генетическая теория* — генетика теориясе.

**ГЕНИА'ЛЬНО** *нареч.*— даһиларча, гениаль рәвештә.

**ГЕНИА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — даһилык, гениальлек.

**ГЕНИА'ЛЬНЫЙ** — 1. (*обладающий гением*) — гениаль, даһи; 2. (*о произведении*) бик югары сыйфатлы; 3. (*чрезвычайно удачный*) бик уңышлы, бик үткен (мәсәлән, фикер).

**ГЕ'НИЙ** *м.*— 1. даһилык; *полководческий гений* — гаскәри даһилык (гаскәрләр белән

җитәкчелек итүдәге даһилык); 2. гений, даһи; *Ломоносов — гений русской науки* — Ломоносов — рус фәненең даһие.

**ГЕНОЦИ'Д** *м. полит.* — геноцид (бүтән расадан, бүтән милләттән яки башка диндә булган халыкның аерым төркемнәрен масса күләмдә кыру; империалистик буржуазия тарафыннан кешеләргә каршы эшләнә торган бу коточкыч авыр җинаять фашизм һәм расизм белән органик рәвештә бәйләнгән).

. **ГЕОБОТА'НИКА** *ж. мн.* нет — геоботаника (үсемлекләрнең таралышын, составын, үзгәрешен климат һәм туфрак үзенчәлекләренә бәйләп өйрәнә торган фән).

**ГЕО'ГРАФ** *м.* — географ (география белгече; география укытучысы).

**ГЕОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — географик, география ... -ы; *географическое понятие* — географик төшенчә; *географический кабинет* — география кабинеты.

**ГЕОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — география (җир шарын, аның өстендә булган геологик күренешләрне, климатны, җанлы табигатьне һ. б. өйрәнә торган фән). ◇ **Физическая география** — физик география (җир өстенең табигатен өйрәнә торган фән). **Экономическая география** — экономик география (кешелек җәмгыятенең хуҗалык эшчәнлеген төрле сыйнфый-экономик шартлардан чыгып һәм хуҗалык күренешләрен аларның географик бүленешләренә бәйләп өйрәнә торган фән). **Лингвистическая география** — лингвистик география (телнең һәрбер аерым күренешенең таралу чикләрен өйрәнә торган фән).

**ГЕОДЕЗИ'СТ** *м.* — геодезист, геодезия белгече.

**ГЕОДЕЗИ'ЧЕСКИЙ** — геодезия ... -ы; *геодезический инструмент* — геодезия инструменты.

**ГЕОДЕ'ЗИЯ** *ж. мн.* нет — геодезия; *высшая геодезия* — югары геодезия (җир шарының формасын һәм зурлыгын өйрәнә торган фән); *низшая геодезия* — башлангыч геодезия (җир өстенең аерым мәйданнарын үлчи һәм аларның планын, картасын төшерә торган фән, топография).

**ГЕОДИНА'МИКА** *ж. мн.* нет, *геол.* — геодинамика (1. киң мәгънәдә — геофизика; 2. тар мәгънәдә — хәзерге дәвердәге геологик процессларны физик яктан тикшерә торган фән).

**ГЕО'ЛОГ** *м.* — геолог (геология белгече; геология укытучысы).

**ГЕОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — геология... -ы, геологик; *геологическая наука* — геология фәне; *геологические разведки* — геологик разведкалар.

**ГЕОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — геология (җир шарының кабыгын, шулай ук анда була торган үзгәрешләрне һәм файдалы казылмаларны эзләп табу методларын өйрәнә торган фән).

**ГЕОЛОГОРАЗВЕ'ДОЧНЫЙ** — геология разведкасы ... -ы; *геологоразведочные работы* — геология разведкасы эшләре.

**ГЕОМАГНЕТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *физ.* — геомагнетизм, җир магнетизмы.

**ГЕО'МЕТР** *м.* — геометр (геометрия белгече).

**ГЕОМЕТРИ'ЧЕСКИЙ** — геометрик; *геометрические тела* — геометрик җисемнәр (шар, пирамида һ. б.).

**ГЕОМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет — геометрия (математиканың бер бүлеге).

**ГЕОМОРФОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — геоморфология (физик географиянең бер бүлеге; җир кабыгының рельефын һәм аның үсешен өйрәнә).

**ГЕОПОЛИ'ТИКА** *ж.* — геополитика (империалистларның тышкы политикасын географик фактларга сылтап аңлатырга һәм аларның басып алу, талау политикасын акларга маташучы, фәнни булмаган, реакцион теория).

**ГЕО'РГИКИ** *лит. истор.* — георгиклар (авыл тормышын, авыл хуҗалыгын мактап язылган антик шигырьләр).

**ГЕОРГИ'Н** *м.*, **ГЕОРГИ'НА** *ж. бот.* — георгин, дәлия (бакча гөле).

**ГЕОФИ'ЗИКА** *ж. мн.* нет — геофизика (җир шарының физик үзлекләрен һәм аның өске кабыгындагы, сулардагы һәм атмосферадагы процессларны өйрәнә торган фән).

**ГЕОФИЗИ'ЧЕСКИЙ** — геофизик ... ; *геофизические методы* — геофизик методлар.

**ГЕОХИМИ'ЧЕСКИЙ** — геохимик, геохимия ...-ы; *геохимический кабинет* — геохимия кабинеты.

**ГЕОХИ'МИЯ** *ж. мн.* нет — геохимия (җир шарындагы химик элементларның тарихын һәм аларның җир кабыгында таралу законнарын өйрәнә торган фән).

**ГЕОЦЕНТРИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *астр., истор.* — геоцентризм (Җир дөньяның үзәгендә тора, хәрәкәт итми, Кояш һәм башка күк җисемнәре аның тирәсендә әйләнә дигән борынгы ялгыш караш).

**ГЕОЦЕНТРИ'ЧЕСКИЙ** *астр., истор.* — геоцентризм ... -ы; геоцентрик; *геоцентрическая система* — геоцентризм системасы.

**ГЕРА'ЛЬДИКА** *ж. мн.* нет — геральдика (гербларны һәм аларның тарихын өйрәнү).

**ГЕРАЛЬДИ'ЧЕСКИЙ** — геральдик, геральдика ... -ы, герблар...-ы; *геральдический атлас* — геральдика атласы, герблар атласы.

**ГЕРА'НЬ** *ж. бот.* — яран, ярангөл (бүлмә гөле).

**ГЕРБ** *м.* — герб (дәүләтнең флаг, акча, печать һ. б. шундый нәрсәләргә төшерелә торган махсус билгесе, рәсми эмблемасы; аерым шәһәрләрнең, өлкәләрнең һ. б. да герблары булуы мөмкин).

**ГЕРБАРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *бот.* — гербаризация (гербарий төзү өчен үсемлекләр җыю һәм киптерү).

**ГЕРБАРИЗИ'РОВАТЬ** *несов. бот.* — гербарий өчен үсемлекләр җыю.

**ГЕРБА'РИЙ** *м. бот.* — гербарий (киптерелгән үсемлекләр коллекциясе).

**ГЕ'РБОВЫЙ** — гербовый, гербле; *гербовая марка* — гербовый марка; *гербовая печать* — гербле печать.

**ГЕРКУЛЕ'С** I *м.*— 1. Геркулес (грекларның гадәттән тыш көчле булган мифик герое Гераклның латинча исеме); 2. *перен.* геркулес (гадәттән тыш көчле кеше).

**ГЕРКУЛЕС** II *м. астр.*— Геркулес (күкнең төньяк ярымшарындагы йолдызлык).

**ГЕРКУЛЕ'СОВСКИЙ** — геркулес ... -ы; *геркулесовская сила* — геркулес көче.

**ГЕРКУЛЕ'СОВЫ СТОЛБЫ'** или **СТОЛПЫ'** — Геркулес баганалары (Гибралтар бугазының ике як ярындагы ике тау; борынгы греклар Гибралтар яр буен „җир чите" дип уйлаганнар). ◇ **Дойти до геркулесовых столпов**—берәр эшнең чигенә барып җиту; ахмаклыкка барып җитү.

**ГЕРМАНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *лингв. лит.*— германизм (герман телләреннән алынган сүз яки әйтелмә; герман телләрендәгечә төзелгән әйтелмә).

**ГЕРМАНИ'СТ** *м. филол.* — германист (герман телләре һәм әдәбияты белгече).

**ГЕРМАНИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *филол.*— германистика (герман телләрен, әдәбиятын һәм культурасын өйрәнә торган фән).

**ГЕРМАНОФИ'Л** *м.*— германофил (немец телен, гореф-гадәтләрен һ. б. яратучы).

**ГЕРМАНОФИ'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — германофиллык (немец телен, гореф-гадәтләрен һ. б. ярату).

**ГЕРМАНОФО'Б** *м.*— германофоб (немец теленә, гореф-гадәтләренә һ. б. нәфрәт белән караучы).

**ГЕРМА'НСКИЙ** — 1. Германия ... -ы, немец ... -ы; *германское государство* — Германия дәүләте; 2. герман ... -ы; *германские языки* — герман телләре (немец, инглиз, швед һ. б. телләр).

**ГЕРМА'НЦЫ** *мн.* (*ед.* германец) — 1. германиялеләр; 2. *науч.* германнар (телләре буенча бер-берсенә якын булган Европа халыклары: немецлар, инглизләр, даниялеләр һәм Скандинавия халыклары).

**ГЕРМАФРОДИ'Т** *м.*— гермафродит; кызтәкә, хонса (ике җенесле).

**ГЕРМАФРОДИТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — гермафродитизм, хонсалык (бер кешедә яки хайванда ике җенес органының да булуы).

**ГЕРМЕНЕ'ВТИКА** *ж. мн.* нет — герменевтика (борынгы язмаларны, китапларны, памятникларны уку, аңлату теориясе һәм осталыгы).

**ГЕРМЕТИЗА'ЦИЯ** *ж.* — герметизация (производство җиһазларын һәм биналарны производство процессында барлыкка килә торган зарарлы яки шартлагыч матдәләрне үткәрми торган итеп ясау).

**ГЕРМЕТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. герметик (һава яки сыеклык кермәслек итеп каплана торган); *герметическая посуда* — герметик савыт; 2. серле (мистик характердагы китаплар һәм доктриналар турында).

**ГЕРОИ'ЗМ** *м. мч.* нет — геройлык, батырлык, каһарманлык; *героизм советских воинов* — совет сугышчыларының батырлыгы; *трудовой героизм* — хезмәттәге батырлык.

**ГЕРО'ИКА** *ж. мн.* нет — героика, героик эчтәлек, героик стиль, героик кичерешләр.

**ГЕРОИ'НЯ** *ж.*— 1. к. герой 1; 2. *(главное действующее лицо)* героиня. ◇ **Мать-героиня** — герой-ана.

**ГЕРОИ'ЧЕСКИЙ** — героик, геройларча ...; герой...; *героический труд*—героик хезмәт; *героический подвиг*—геройларча батырлык; *героический пролетариат* — герой пролетариат.

**ГЕРО'Й** *м.*— 1. герой, батыр, каһарман; *герои Великой Отечественной войны* — Бөек Ватан сугышы геройлары; *герой труда* — хезмәт батыры, хезмәт герое; 2. герой; *герой романа* — романның герое. ◇ **Герой не моего романа** — андый кешеләр минем ошамый.

**ГЕРО'ЙСКИ, ГЕРОИ'ЧЕСКИ** *нареч.*— геройларча, батырларча, каһарманнарча.

**ГЕРО'ЙСКИЙ** — геройларча ..., батырларча ...; *геройский поступок* — геройларча эш. ◇ **Геройский дух** — күтәренке рух.

**ГЕРО'ЙСТВО** *ср. мн.* нет — геройлык, батырлык, каһарманлык.

**ГЕРО'ЙСТВОВАТЬ** *несов.*— герой булып кылану, әтәчләнү.

**ГЕРО'ЛЬД** *м. истор.*— герольд, хәбәр бирүче, яр салучы, нидачы (урта гасырда сарай боерыкларын һәм хәбәрләрне кычкырып, яр салып, белдереп йөрүче).

**ГЕ'РЦОГ** *м.*— герцог (Көнбатыш Европада югары катлау дворяннар һәм аерым өлкә биләүче князьләр титулы).

**ГЕ'РЦОГСКИЙ** — герцог ... -ы; *герцогский титул* — герцог титулы.

**ГЕ'РЦОГСТВО** *ср.*— герцоглык (1. башында герцог тора торган өлкә, дәүләт; 2. герцоглык дәрәҗәсе).

**ГЕСТА'ПО** *ср.* нескл. *мн.* нет — гестапо (фашистлар власть башында торган вакытта Германия дәүләтенең яшерен полициясе).

**ГЕСТА'ПОВЕЦ** *м.*— гестапочы.

**ГЕСТА'ПОВСКИЙ** — гестапо ... -ы; *гестаповский метод* — гестапо методы.

**ГЕТЕ'РИИ** — гетерийлар (1. борынгы Грециядә яшерен политик союзлар; 2. XIX йөз башларында Төркия изүеннән котылу максаты белән Грециядә оештырылган яшерен патриотик оешмалар).

**ГЕ'ТМАН** *м. истор.*— гетман (1. XVI—XVIII йөзләрдә Польшада короллы көчләр баш командующие; 2. XVI йөзнең ахырында Украинада Запорожье казакларының сайлап куелган башлыгы; XVII йөз башыннан — Украина дәүләте башлыгы).

**ГЕ'ТМАНСКИЙ** *истор.*— гетман ... -ы; *гетманская власть* — гетман власте.

**ГЕ'ТМАНСТВО** *ср. мн.* нет, *истор.*— гетманлык, гетман хакимлеге, гетман идарәсе (власте).

**ГЕ'ТМАНЩИНА** *ж. мн.* нет, *истор.*— гетманчылык (1. Украинаның XVII йөздә гетман идарәсе астында Москва дәүләте составына кергән өлеше; 2. 1918 елда

Украинада Германия империалистлары тарафыннан урнаштырылган контрреволюцион хәрби диктатура).

**ГЕ'ТРЫ** *мн.*— гетр (ботинка өстеннән киелә торган җылы куныч).

**ГЕШЕ'ФТ** *м. разг. ирон.*— гешефт (1. вак-төяк эш, табышлы эш, сәүдә, спекуляция; 2. һәр эштә үз файдасын гына кайгырту).

**ГИАЦИ'НТ** *м.*— 1. *(цветок)* сөмбел, сөмбел гөле; 2. *(драгоценный камень)* гиацинт (кызыл, соры яки саргылт-кызыл төстәге асылташ).

**ГИАЦИ'НТОВЫЙ** — 1. сөмбел ... -ы; *гиацинтовый цветок* — сөмбел чәчәге; 2. гиацинт кашлы; *гиацинтовый перстень* — гиацинт кашлы йөзек.

**ГИ'БЕЛЬ** I *ж.*— һәлакәт, үлем, үлеш.

**ГИ'БЕЛЬ** II *ж. разг.*— бик күп, тулып ята; чиксез, бетмәс-төкәнмәс, исәбе-хисабы юк; *там гибель комаров* — анда озынборыннарның исәбе-хисабы юк.

**ГИ'БЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — һәлакәтлелек.

**ГИ'БЕЛЬНЫЙ** — 1. һәлакәтле, һәлакәткә илтә торган, куркыныч, баш бетәрлек; 2. *(трагический)* фаҗигалы, трагик.

**ГИ'БКИЙ** — 1. *(упругий)* сыгылмалы, бөгелмәле, эластик, бөгелүчән, пеше; 2. *перен.* тапкыр, сизгер, үткен, зирәк, җитез; *гибкий ум* — зирәк акыл; 3. *перен.* йомшак табигатьле, чит тәэсиргә тиз бирелүчән.

**ГИ'БКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(упругость)* сыгылучанлык, бөгелүчәнлек; 2. *перен.* зирәклек, сизгерлек, тиз җайлана алучанлык, читен мәсьәләне тиз хәл итә (кыла) алучанлык; *проявить гибкость* — зирәклек күрсәтү.

**ГИ'БЛЫЙ** *разг.*— барып чыкмый торган, баш бетәрлек, бетүгә йөз тоткан, ышанычсыз, бернигә яраксыз; *гиблое дело* — баш бетәрлек эш.

**ГИ'БНУТЬ** *несов.*— һәлак булу, кырылу, үлү, бетү.

**ГИБРИ'Д** *м. биол.*— гибрид (төрле токым хайваннарны, яки төрле сорт үсемлекләрне кушудан килеп чыккан тума яки үсемлек, мәсәлән, ат белән ишәк кушылу нәтиҗәсендә туган качыр).

**ГИБРИДИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — гибридизация, гибридлаштыру (төрле токым хайваннарны, төрле сорт үсемлекләрне бергә кушып орлыкландыру юлы белән гибрид алу).

**ГИБРИ'ДНЫЙ** — гибрид ... , гибридлашкан; *гибридное потомство* — гибрид нәсел.

**ГИБРИДОЛО'ГИЯ** *ж.*— гибридология (гибридлар турындагы тәгълимат).

**ГИГА'НТ** *м.*— 1. гигант (грек мифологиясендә: бик зур, гадәттән тыш көчле җан иясе); 2. *перен.* олы гәүдәле кеше, алып батыр; 3. үтә зур, бик зур, гаять зур; *дом-гигант*—гаять зур йорт.◇**Гигант мысли** — күренекле фикер иясе, күренекле фән эшлеклесе.

**ГИГАНТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — гигантизм (кешеләрдә, терлекләрдә, үсемлекләрдә нормадан тыш үсү).

**ГИГА'НТСКИ** *нареч.*— чиктән тыш, гадәттән тыш; *гигантски трудная задача* — чиктән тыш кыен мәсьәлә.

**ГИГА'НТСКИЙ** — гаять зур, бик зур, чиксез зур; гигант ... ; *гигантский станок* — гаять зур станок; *идти вперёд гигантскими шагами* — бик зур адымнар белән алга бару.

**ГИГИЕ'НА** *ж. мн.* нет — гигиена (1. сәламәтлекне саклау, сәламәтлеккә тәэсир итә торган тормыш шартлары һәм авыруны булдырмау чаралары турындагы тәгълимат; 2. сәламәтлекне саклау чаралары).

**ГИГИЕНИ'СТ** *м.*— гигиенист (гигиена белгече).

**ГИГИЕНИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гигиеналылык.

**ГИГИЕНИ'ЧЕСКИЙ** — гигиена ... -ы; гигиеник; *гигиенические меры* — гигиена чаралары; *гигиенический образ жизни* — гигиеник көнкүреш.

**ГИГИЕНИ'ЧНЫЙ** — гигиеналы, гигиена кагыйдәләренә туры килә торган.

**ГИД** *м.*— 1. *(проводник)* юл күрсәтүче; 2. *устар. (путеводитель)* юл күрсәткеч (китап).

**ГИ'ДРА** *ж.*— 1. *миф.* аждаһа (борынгы грек мифологиясендә күп башлы елан); 2. *зоол.* гидра (тозсыз суларда яшәүче умырткасыз хайван).

**ГИДРА'ВЛИКА** *ж. мн.* нет, *физ.*— гидравлика (суның тигезлек саклау һәм аның хәрәкәт итү законнарын практикада куллану ысулларын өйрәнә торган фән).

**ГИДРАВЛИ'ЧЕСКИЙ** *тех.*— 1. гидравлика ... -ы; *гидравлические исследования* — гидравлика тикшеренүләре; 2. гидравлик, су көче белән эшли торган; *гидравлический пресс* — гидравлик пресс; *гидравлический двигатель* — гидравлик двигатель (су көче белән эшли торган двигатель).

**ГИДРА'НТ** *м. тех.*— гидрант (урамнарга су сибү яки янгын сүндерү өчен водопровод линиясенә куела торган колонка яки кран).

**ГИДРОАВИА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — гидроавиация, су авиациясе (су өстенә төшә һәм су өстеннән очып китә ала торган самолётлар).

**ГИДРОАЭРОДРО'М** *м. ав.*— гидроаэродром (диңгездә, күлдә яки зур елгада гидросамолётлар өчен корылган аэродром).

**ГИДРОАЭРОПЛА'Н** *м. ав.*— гидроаэроплан (суга төшә һәм судан күтәрелә ала торган аэроплан).

**ГИДРОБИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — гидробиология (суда яшәүче организмнарның һәм тирә-юньдәге мохитның үзара мөнәсәбәтләрен өйрәнә торган фән).

**ГИДРОБИО'НТЫ** *мн.*— гидробионтлар (суда яшәүче организмнар).

**ГИДРОГЕНЕРА'ТОР** *м.*— гидрогенератор (су хәрәкәте энергиясен электр энергиясенә әверелдерә торган генератор).

**ГИДРОГЕОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — гидрогеология (геологиянең бер тармагы — җир асты суларының килеп чыгуын, хәрәкәтен,

аларның химик һәм физик үзенчәлекләрен өйрәнә).

**ГИДРО'ГРАФ** *м.*— гидрограф (1. гидрография белгече; 2. су агымы тизлеген үлчи торган прибор).

**ГИДРОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — гидрография ... -ы; гидрографик; *гидрографическая карта* — гидрографик карта.

**ГИДРОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — гидрография (1. географиянең җир өсте суларын өйрәнә торган бүлеге; 2. карталар төзү максаты белән диңгезләрне, күлләрне, елгаларны төшереп алу һәм тасвирлау).

**ГИДРОДИНА'МИКА** *ж. мн.* нет, *тех.*— гидродинамика (гидромеханиканың сыеклыкларның һәм газларның хәрәкәт итүен өйрәнә торган бүлеге).

**ГИДРОДИНАМИ'ЧЕСКИЙ** *тех.*— гидродинамик; *гидродинамическое давление* — гидродинамик басым.

**ГИДРО'ЛОГ** *м.*— гидролог (гидрология белгече).

**ГИДРОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — гидрология ... -ы; гидрологик; *гидрологический институт* — гидрология институты; *гидрологическая карта* — гидрологик карта.

**ГИДРОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — гидрология (җир шарындагы суларны һәм табигатьтә суның әйләнеп йөрешен өйрәнә торган фән).

**ГИДРОМЕТЕОРОЛО'ГИЯ** *ж.*— гидрометеорология (атмосферадагы суның әйләнеп йөрешен өйрәнә торган фән).

**ГИДРОМЕТРИ'ЧЕСКИЙ** — гидрометрик; *гидрометрическая станция* — гидрометрик станция.

**ГИДРОМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет — гидрометрия (гидрологиянең бер бүлеге; агым суларның агым тизлеген, тирәнлеген, расходын үлчәү эшләре белән шөгыльләнә).

**ГИДРОМЕХА'НИКА** *ж. мн.* нет, *тех.*— гидромеханика (сыек матдәләрнең тигезлек саклауларын һәм хәрәкәтләрен өйрәнә торган фән).

**ГИДРОПЛА'Н** *м. ав.*— гидроплан, гидроаэроплан.

**ГИДРОСАМОЛЁТ** *м.*— гидросамолёт (су өстенә төшә һәм су өстеннән очып китә ала торган самолёт).

**ГИДРОСТА'НЦИЯ** *ж. тех.*— гидростанция (электр энергиясе эшләп чыгару өчен су хәрәкәте көченнән файдалана торган электростанция).

**ГИДРОСФЕ'РА** *ж.*— гидросфера (җир шарындагы барлык сулар: океаннар, диңгезләр, күлләр, елгалар).

**ГИДРОТЕ'ХНИК** *м. тех.*— гидротехник (гидротехника белгече).

**ГИДРОТЕ'ХНИКА** *ж. мн.* нет, *тех.*— гидротехника (техниканың табигатьтәге судан һәм су энергиясеннән файдалану турындагы бүлеге).

**ГИДРОТЕХНИ'ЧЕСКИЙ** *тех.*— гидротехник; *гидротехнические сооружения* — гидротехник корылмалар.

**ГИДРОУ'ЗЕЛ** *м.*— гидроузел (су хуҗалыгы бурычларын үтәү өчен зур елгага яки каналга корылган барлык корылмалар).

**ГИДРОФЛО'Т** *м.*— гидрофлот (гидропланнардан тора торган һава флоты).

**ГИДРОФО'БИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— гидрофобия, судан курку (котыру авыруы).

**ГИДРОЭЛЕКТРИ'ЧЕСКИЙ** *тех.*— гидроэлектрик; *гидроэлектрическая станция* — гидроэлектрик станция (агым суның энергиясен электр энергиясенә әверелдерә торган корылма).

**ГИДРОЭНЕ'РГИЯ** *ж.*— гидроэнергия, су энергиясе.

**ГИЕ'НА** *ж. зоол.*— сыртлан (ерткыч җанвар).

**ГИ'КАТЬ** *несов. разг.*— һайт дип кычкыру.

**ГИ'КНУТЬ** *сов.* и *однокр., разг.*— һайт дип кую.

**ГИ'ЛЬДИЯ** *ж. истор.*— гильдия (1. урта гасырларда купецларның союзы; 2. революциягә кадәр Россиядә купецлар дәрәҗәсе).

**ГИ'ЛЬЗА** *ж.*— гильза (1. патронның, снарядның дары яки башка шартлагыч тутырылган өлеше; 2. тәмәке тутырып папирос ясау өчен эшләнгән кәгазь көпшә).

**ГИ'ЛЬЗОВЫЙ** — гильза ... -ы; *гильзовая бумага* — гильза кәгазе.

**ГИЛЬОТИ'НА** *ж.*— гильотина (үлем җәзасына хөкем ителгән кешеләрне баш кисү юлы белән үтерү машинасы; 1792 елда Франциядә буржуаз революция вакытында кертелгән).

**ГИЛЬОТИНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— башны гильотина белән кисү.

**ГИЛЯ'КИ** *м. мн.* (*ед.* гиляк) — гиляклар (СССРның Ерак Көнчыгышында яшәүче нивх халкының элекке исеме).

**ГИЛЯ'ЦКИЙ** — гиляк ... -ы; *гиляцкий язык* — гиляк теле.

**ГИМН** *м.*— 1. гимн (берәр дәүләтнең яки сыйныфның бердәмлеген гәүдәләндерү билгесе итеп алынган тантаналы җыр); *государственный гимн* — дәүләт гимны; *„Интернационал“ — гимн Коммунистической партии* — „Интернационал“— Коммунистлар партиясенең гимны; 2. мактау җыры.

**ГИМНАЗИ'СТ** *м. устар.*— гимназист (гимназиядә укучы).

**ГИМНАЗИ'СТКА** *ж. устар.*— гимназистка (гимназиядә укучы кыз).

**ГИМНАЗИ'ЧЕСКИЙ** — гимназия ... -ы, гимназист ... -ы, гимназистлар ... -ы; *гимназическое образование* — гимназия белеме; *гимназические проказы* — гимназист шаянлыклары.

**ГИМНА'ЗИЯ** *ж.*— гимназия (кайбер буржуаз илләрдә һәм революциягә кадәр Россиядә урта мәктәп).

**ГИМНА'СТ** *м.*— гимнаст (гимнастикага оста кеше; гимнастиканы профессия итеп алган кеше).

**ГИМНАСТЁРКА** *ж.*— гимнастёрка.

**ГИМНА'СТИКА** *ж. мн.* нет — гимнастика (организмны ныгыту өчен эшләнә торган тән хәрәкәтләре; шундый хәрәкәтләр системасы).

**ГИМНАСТИ'ЧЕСКИЙ** — гимнастика ... -ы; *гимнастический зал* — гимнастика залы.

**ГИНЕКО'ЛОГ** *м. мед.* — гинеколог (гинекология врачы).

**ГИНЕКОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — гинекологик, гинекология ... -ы; *гинекологическая операция* — гинекологик операция; *гинекологическая клиника* — гинекология клиникасы.

**ГИНЕКОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — гинекология (хатын-кыз авыруларын һәм аларны дәвалау юлларын өйрәнә торган фән).

**ГИПЕ'РБОЛА** *ж.* — гипербола (1. *мат.* конусны аның ике тәзүчесенә параллель булган яссылык белән кистергәндә барлыкка килә торган кәкре сызык; 2. *лит.* чиктән тыш арттырып, көчәйтеп сурәтләү, күпертү; мәсәлән, „янгыр чиләкләп койды").

**ГИПЕРБОЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — үтә арттыру, үтә күпертү.

**ГИПЕРБОЛИ'ЧЕСКИЙ** — 1. гипербола ... -ы; *гиперболическое сечение* — гипербола киселе (*мат.*); 2. гиперболик; *гиперболический стиль* — гиперболик стиль; 3. к. гиперболичный.

**ГИПЕРБОЛИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — үтә арттырылганлык, үтә күпертелгәнлек.

**ГИПЕРБОЛИ'ЧНЫЙ** — бик арттырылган, үтә кабартылган, үтә күпертелгән.

**ГИПЕРТО'НИК** *м. мед.* — гипертоник (гипертония белән авыручы).

**ГИПЕРТОНИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — гипертония (кан басымының күтәрелүе).

**ГИПЕРТРОФИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. биол. мед.* — гипертрофияләнү, артык зураю, үсү (берәр орган турында).

**ГИПЕРТРОФИ'ЧЕСКИЙ** *биол. мед.* — гипертрофик; *гипертрофическое явление* — гипертрофик күренеш.

**ГИПЕРТРОФИ'Я** *ж. мн.* нет — гипертрофия (1. *мед. биол.* авыру яки артык эш нәтиҗәсендә нинди дә булса органның чиктән тыш үсүе, зураюы; 2. *перен.* нинди дә булса сыйфатның артык үсүе, зураюы).

**ГИПНО'З** *м. мн.* нет — 1. гипноз (а. чит бер кешенең ихтыяры белән йоклагансыман хәлгә килү; б. тәэсир итеп йоклата алу куәте, йоклату ысулы); 2. *перен.* тәэсир көче.

**ГИПНОТИЗЁР** *м.* — гипнотизёр, гипнозчы, гипноз ясаучы; гипноз белән дәвалаучы врач.

**ГИПНОТИЗИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — гипнозлау (1. гипноз ясау, гипноз белән йоклату; 2. көчле йогынты ясау, үз ихтыярына буйсындыру).

**ГИПНОТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд., книж.* — гипнозлану.

**ГИПНОТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — гипнотизм (1. гипноз күренешләре турындагы тәгълимат; 2. гипноз күренешләре; 3. гипноз осталыгы).

**ГИПНОТИ'ЧЕСКИЙ** — гипноз ... -ы; гипнотизм ...-ы; *гипнотический сеанс* — гипноз сеансы; *гипнотические явления* — гипнотизм күренешләре.

**ГИПОТА'КСИС** *м. грам.* — гипотаксис (җөмләләрнең берсенең икенчесенә буйсынуы).

**ГИПО'ТЕЗА** *ж.* — 1. гипотеза (тулысынча исбат ителеп җитмәгән булса да, беркадәр ихтималлыгы булган һәм кайбер күренешләрне дөрес аңларга ярдәм итә торган гыйльми фикер); 2. *перен.* гөман, фараз; *строить гипотезы* — гөман итү, фараз итү.

**ГИПОТЕТИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — гипотезага нигезләп.

**ГИПОТЕТИ'ЧЕСКИЙ** — гипотезага нигезләнгән; гөман ителгән, фараз ителгән.

**ГИПОТЕТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гипотезага нигезләнгәнлек, фараз итүгә нигезләнгәнлек.

**ГИПОТЕТИ'ЧНЫЙ** — к. гипотетический.

**ГИППОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *вет.* — гиппология (атның тән төзелешен, атларны үрчетү, яхшырту һ. б. өйрәнә торган фән).

**ГИППОПОТА'М** *м. зоол.* — к. бегемот.

**ГИПС** *м. мн.* нет — 1. *мин.* гипс (ак яки сары төстәге минерал); 2. (*скульптурный слепок*) гипстан ясалган сын; 3. *только ед. мед.* гипс (гипстан ясалган бәйләвеч, сынган аяк-кулны яки берәр башка органны бәйләп кую өчен); *положить руку в гипс* — кулны гипс белән бәйләү, гипска салу.

**ГИПСОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *мед.* гипска салу; 2. гипс белән ашлау; *гипсовать почву* — туфракны гипс белән ашлау; 3. гипс салу (виноград аракысына).

**ГИ'ПСОВЫЙ** — гипс ... , гипстан ясалган; *гипсовая повязка* — гипс бәйләвеч.

**ГИПЮ'Р** *м. мн.* нет — гипюр (күпертеп эшләнгән челтәр).

**ГИПЮ'РОВЫЙ** *текст.* — гипюр ... ; күпертеп эшләнгән; *гипюровые кружева* — гипюр челтәр, күпертеп эшләнгән челтәр.

**ГИРЕВИ'К** *м. спорт.* — гер күтәрүче.

**ГИРЕВО'Й** — 1. гер белән эшләнә торган; *гиревые упражнения* — гер белән эшләнә торган күнегүләр; 2. герләр ... -ы; герле; *гиревой комплект* — герләр комплекты; *гиревые весы* — герле үлчәү.

**ГИ'РЛО** *ср. геогр. обл.* — тармак (Кара һәм Азов диңгезләренә коя торган елгаларга карата әйтелә); *дунайские гирла* — Дунай тармаклары.

**ГИРЛЯ'НДА** *ж.* — гирлянда (чәчәкләр үреме, шуңа охшатып ясалган орнамент).

**ГИ'РЯ** *ж.* — гер.

**ГИСТО'ЛОГ** *м. биол.* — гистолог (гистология белгече).

**ГИСТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *биол.* — гистология (кеше һәм хайван организмы тканьнарының микроскопик төзелешен өйрәнә торган фән).

**ГИТА'РА** *ж. муз.* — гитара (кыллы музыка коралы).

**ГИТАРИ'СТ** *м.* — гитарачы, гитарада уйнаучы.

**ГИ'ЧКА** *ж. мор. спорт.* — гичка (ишкәкле, тиз йөрешле җиңел көймә).

**ГЛАВА'** I *ж.* — 1. *устар.* к. голова; 2. башлык, житәкче; *глава учреждения* — учреждение башлыгы (житәкчесе); 3. (*вершина, верх скалы*) түбә, баш; 4. (*купол*) чиркәү гөмбәзе, чиркәү башы. ◇ **Во главе** — житәкчелегендә. **Ставить во главу угла** — иң төп (иң әһәмиятле) мәсьәлә итеп тану.

**ГЛАВА'** II *ж.* — бүлек.

**ГЛАВ'АРЬ** *м. неодобр.* — атаман, башлык, башлап жибәрүче, башлап йөрүче.

**ГЛАВЕ'НСТВО** *ср. мн.* нет — хакимлек, өстенлек.

**ГЛАВЕ'НСТВОВАТЬ** *несов. книж.* — башында тору (берәр эшнең); өстенлек итү, житәкчелек итү, идарә итү.

**ГЛАВНЕ'ЙШИЙ** — иң төп, иң әһәмиятле, иң мөһим.

**ГЛА'ВНОЕ** *ввод. сл.* — барыннан да бигрәк, башлыча, иң әһәмиятлесе.

**ГЛАВНОКОМА'НДУЮЩИЙ** *м.* — баш командующий, главнокомандующий.

**ГЛА'ВНЫЙ** — 1. (*основной*) төп, нигез, иң зур, иң әһәмиятле, иң мөһим; 2. баш; *главный врач* — баш врач. ◇ **Главная квартира** — верховный командующийның штабы (ставкасы). **Главным образом** — башлыча. **Главное предложение** *грам.* — баш жөмлә.

**ГЛАГО'Л** *м.* — 1. *грам.* фигыль; 2. *устар.* сөйләм, сүз. ◇ **Многократный глагол** — кабатлаулы фигыль. **Однократный глагол** — кабатлаусыз фигыль. **Производный глагол** — ясалма фигыль.

**ГЛАГО'ЛИЦА** *ж. мн.* нет, *филол.* — глаголица (борынгы славян әлифбасы).

**ГЛАГОЛИ'ЧЕСКИЙ** — глаголица ... -ы; глаголица хәрефләре белән язылган; *глаголические буквы* — глаголица хәрефләре; *глаголическая рукопись* — глаголица хәрефләре белән язылган кульязма.

**ГЛАГО'ЛЬНЫЙ** — фигыль ... -ы; *глагольная форма* — фигыль формасы.

**ГЛА'ДЕНЬКИЙ** — шоп-шома, шома гына.

**ГЛАДИА'ТОР** *м. истор.* — гладиатор (борынгы Римда: циркта ерткыч хайваннар белән яки үзе кебек үк икенче бер кол белән көрәшүче кол).

**ГЛАДИ'ЛКА** *ж.* — шомарткыч, ялтыраткыч.

**ГЛАДИ'ЛЬНЫЙ** — үтүкләү ...-ы; *гладильная доска* — үтүкләү тактасы.

**ГЛАДИ'ЛЬЩИК** *м.*, **ГЛАДИ'ЛЬЩИЦА** *ж.* — үтүкләүче.

**ГЛА'ДИТЬ** *несов.* — 1. (*утюгом*) үтүкләү; 2. (*ласкать*) сыпыру, сыйпау. ◇ **Гладить по головке** *перен. разг.* — юл кую, азындыру. **Гладить против шерсти** *перен. разг.* — каршы әйтү.

**ГЛА'ДКИЙ** — 1. (*ровный*) шома, тигез; 2. (*о материи*) бизәксез, бертөсле; 3. *перен.* (*плавный. незатруднённый*) жиңел, шома, шома төзелгән (мәсәлән, шигырь); 4. *перен. разг.* симез, көр, тулы; *гладкая лошадь* — симез ат. ◇ **С него взятки гладки** *разг.* — аңардан сорап та торасы юк, барыбер ала алмассың.

**ГЛА'ДКО** *нареч.* — 1. шома итеп, тигез итеп; *гладко выстругать доску* — тактаны шома итеп стругалау; 2. (*без затруднения*) шома гына, ул-бусыз, тавыш-тынсыз, тыныч кына; төртелмичә генә.

**ГЛАДКОСТВО'ЛЬНЫЙ** — шома көпшәле (корал).

**ГЛА'ДКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. шомалык, тигезлек; 2. *перен.* жиңеллек, шомалык.

**ГЛАДЫ'Ш** *м.* — 1. *зоол.* су кандаласы (бөжәк); 2. (*о камне*) шома таш; 3. *обл.* (*о ребёнке*) түп-түгәрәк бала, ит бүкәне.

**ГЛАДЬ** I *ж. мн.* нет — киң тигезлек (мәсәлән, су өсте, боз өсте). ◇ **Тишь да гладь** *перен.* — тып-тыныч тормыш, бик тыныч тормыш, жилсез-давылсыз тормыш.

**ГЛАДЬ** II *ж. мн.* нет — тоташтан чигү.

**ГЛА'ЖЕНЫЙ** — 1. үтүкләнгән; 2. тигезләнгән; 3. шомартылган.

**ГЛАЗ** *м.* (*мн.* глазá) — 1. (*орган зрения*) күз; 2. *только ед.* (*надзор*) күз булу, күзколак булу. ◇ **Невооружённым глазом** — гади күз белән (күзлексез, бинокльсез һ. б.). **Хоть глаз выколи** — дөм караңгы, күзгә төртсәң дә күренми. **На глаз** — чама белән. **Сказать правду в глаза** — туп-туры әйтү, күзенә карап әйтү. **В глаза не видал** — күргәнем дә юк, беркайчан да күргәнем юк, һичкайчан да күргәнем юк; гомеремдә күргәнем юк. **За глаза** — үзе юкта, артында; *говорить за глаза* — үзе юкта сөйләү, артында сөйләү. **За глаза (довольно)** — артыгы белән житәрлек. **В глазах** *кого или чьих* — каршында; *высоко стоять в глазах товарищей* — иптәшләре каршында югары тору. **Между глаз** *простореч.* — күз ачып йомганчы; *деревня сгорела между глаз* — авыл күз ачып йомганчы янып бетте. **Лезть на глаза** *кому разг.* — күзгә керү (үзен күрсәтергә тырышу). **На глазах** — күз алдында, каршыда. **Смотреть чьими-н. глазами** — кеше карашы (фикере) белән эш итү, үз фикере булмау. **С глаз долой** — күз алдыннан кит, югал, күземә күренмә, күземнән югал. **С глазу на глаз** — каракаршы, күзгә-күз, икәүдән икәү генә. **Не в бровь, а (прямо) в глаз** — өстенә басты, туп-туры. **Хозяйский глаз** — хужаларча карау. **Закрывать глаза** — игътибар бирмәү, күз йому, күрмәү, күрмәмешкә салыну, күрмәскә тырышу. **Закрыть глаза** *на что-н.* — күз йому. **Закрыть глаза** *кому-н. перен.* — үлгәндә авызына су салу. **Попасться на глаза** — күзгә чалыну, очрау. **Иди, куда глаза глядят** — к. глядеть. **Острый глаз** — үткен күз. **Дурной глаз** — яман күз. **Во все глаза глядеть** — дүрт күзләп карау (көтү). **Смеяться в глаза** — күзгә карап көлү. **Все глаза проглядела** — күзләрем талып бетте, күз керфекләрем талганчы карадым. **Не попадайся в глаза** — күземә күренмә, күземә күренәсе булма. **Отвести глаза** — игътибарын читкә юнәлтү. **И глазом не успел моргнуть** — күз ачып йомганчы. **В глазах обмануть** — күзгә карап алдау. **Сбыть с глаз** —

күздән югалту, куып җибәрү. **Не спускать глаз** — 1. күз дә алмау; 2. күз-колак булу. **Иметь перед глазами** — күз алдында тоту. **Пускать пыль в глаза** — күз буяу. **Потупить глаза** — аска карау. **Пялить глаза** — күз акайту, күз чекрәйтү. **Глаза шире брюха** — ач күз, комсыз. **Потерять глаза** — күзсез калу, сукыраю. **Мерить глазами** *кого-либо* — баштанаяк күз йөртеп алу. **Глаза разбегаются** — кайсына карарга да белмәү. **Хлопать глазами**—авыз ачып тору. **Колоть в глаза** — битәрләү, шелтәләү.

**ГЛАЗА'СТЫЙ** *разг.* — 1. (*большеглазый*) зур күзле, шар күзле, акай күзле; 2. (*зоркий*) очлы күзле, үткен күзле, яхшы күрүчән; 3. *простореч.* эре бизәкле.

**ГЛАЗЕ'Т** *м. разг.* — укалы парча, асыл (материя).

**ГЛАЗЕ'ТЬ** *несов. разг.* — карап тору, кызыксынып карап тору; авыз ачып карап тору.

**ГЛАЗИРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. (*посуду*) глазурь (ялтыравык) йөгертү; 2. (*бумагу*) ялтырату; 3. (*торт, пирожное*) ширбәт ягу.

**ГЛАЗИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— 1. глазурь йөгертелү; 2. ялтыратылу; 3. ширбәт ягылу.

**ГЛАЗНИ'К** *м. разг.* — күз врачы, окулист.

**ГЛАЗНИ'ЦА** *ж. анат.* — күз чокыры.

**ГЛАЗНО'Й** — күз ... -ы; *глазной врач* — күз врачы.

**ГЛАЗО'К** *м.* —1. кечкенә күз; 2. (*зачаточная почка картофеля*) күз, күзәнәк, күзчек; 3. *бот.* яфрак бөресе; 4. кечкенә тәрәзә (төрмә ишегендә); 5. (*у иголки*) күз. ◇ **Взглянуть одним глазком** — күз ташлап алу, карап алу, күз кырые белән генә карау, тиз генә карап алу. **Анютины глазки** *бот.* — ала миләүшә. **На глазок** — күз белән чамалап.

**ГЛАЗОМЕ'Р** *м. мн.* нет — күз чамасы, күз үлчәме (ераклыкны күз белән чамалау).

**ГЛАЗОМЕ'РНЫЙ** — күз белән ... ; *глазомерное определение расстояния* — араны күз белән чамалау.

**ГЛАЗУ'НЬЯ** *ж.* — йомырка тәбәсе (йомырканың сарысын агы белән тугыламыйча табага сытып пешерелгән тәбә).

**ГЛАЗУ'РЬ** *ж. мн.* нет — 1. (*на посуде*) глазурь, ялтыравык; 2. (*на торте* и т. п.) шикәр ширбәте (сиробы).

**ГЛА'НДА** *ж. анат.* — гланда, тамак бизе (йоткылыктагы миндальсыман биз, лимфатик төен).

**ГЛАС** *м. устар.* — тавыш, аваз, яңгырау.

**ГЛАСИ'ТЬ** *несов.* — белдерү, хәбәр бирү, хәбәр итү. ◇ **Закон гласит так** — закон болай ди.

**ГЛА'СНО** *нареч.* — һәркемгә белдереп (ишеттереп, кычкырып), ачыктан-ачык, халык алдында.

**ГЛА'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет — билгелелек, ачыклык, һәркемгә (халыкка, җәмәгатьчелеккә) билгеле булу.

**ГЛА'СНЫЙ** I *лингв.* — сузык; *гласные звуки* — сузык авазлар (мәсәлән, а, о, е һ. б.).

**ГЛА'СНЫЙ** II — ачык, халыктан яшерен булмаган, һәркем катнашырга мөмкин булган; *гласный суд* — ачык суд.

**ГЛА'СНЫЙ** III *истор.* — гласный (революциягә кадәр шәһәр думасы члены, шәһәр депутаты; земство члены).

**ГЛАША'ТАЙ** *м.* — 1. *истор.* белдерүче, яр салучы, өндәүче, нидачы (борынгы заманда халыкка рәсми хәбәрләрне белдереп йөрүче); 2. *перен.* белдерүче, яклаучы; *Советский Союз — глашатай мира* — Советлар Союзы — тынычлыкны яклаучы.

**ГЛЕ'ТЧЕР** *м.* — глетчер, бозлык (таулардан шуып төшә торган бозлык).

**ГЛИ'НА** *ж. мн.* нет — кызыл балчык, сутлы балчык.

**ГЛИ'НИСТЫЙ** —кызыл балчыклы, сутлы балчыклы.

**ГЛИ'НИЩЕ** *ср.* — кызыл балчык чокыры, балчык ала торган чокыр.

**ГЛИ'НКА** I *ж. мн.* нет — 1. кызыл балчык кисәге; 2. *тех.* каолин (сутлы балчыкның яхшы сорты; ситсы буяуда кулланыла).

**ГЛИ'НКА** II *ж. зоол. обл.* — кыр күгәрчене.

**ГЛИНОБИ'ТНЫЙ** — балчык ... (вак таш, салам яки чыбык кушып хәзерләнгән балчыктан салынган); *глинобитный сарай*— балчык сарай.

**ГЛИНОВА'ЛЬНЯ** *ж. спец. обл.* — кызыл балчык изү урыны.

**ГЛИНОЛИ'ТНЫЙ** — кызыл балчыктан салынган.

**ГЛИНОМЯ'ЛКА** *ж.* — кызыл балчык изгеч (машина).

**ГЛИНОСОЛО'МА** *ж.* — саламлы балчык (төзү материалы).

**ГЛИ'НЯНЫЙ**—(кызыл) балчыктан ясалган, кызыл балчык ...; *глиняная посуда* — балчыктан ясалган савыт, балчык савыт.

**ГЛИ'ССЕР** *м. мор.* — глиссер (су өстеннән шуып бара торган тиз йөрешле пропеллерлы көймә).

**ГЛИССИ'РОВАНИЕ** *ср.* — су өстеннән шуып бару (глиссер яки гидроплан турында).

**ГЛИ'СТ** *м. разг.* — глист (кеше яки хайван организмында була торган паразит суалчан).

**ГЛИСТА'** *ж. зоол.* —1. к. глист; 2. *перен. вульг. пренебр.* колга, колгасар (ябык озын кеше).

**ГЛИЦЕРИ'Н** *м. мн.* нет— глицерин (майдан химик юл белән алына торган куе сыекча; медицинада һәм техникада кулланыла).

**ГЛИЦЕРИ'НОВЫЙ** — 1. глицерин ...-ы; *глицериновое производство* — глицерин производствосы; 2. глицеринлы; *глицериновое мыло* — глицеринлы сабын.

**ГЛО'БА** *ж. обл.* — бастырык, бастыргыч (салам түбәгә яки кибән өстенә бастырыла торган колга).

**ГЛОБУЛЯ'РНЫЙ** — шарсыман.

**ГЛО'БУС** *м. геогр.* — глобус (җир шарының моделе).

**ГЛОДА'ТЬ** *несов.* 1. (*грызть*) кимерү; 2. *перен.* (*мучить*) колак итен ашау, теңкәгә тию (һаман бер нәрсә турында мыгырдап йөрү); 3. *перен.* (*внутренне терзать*) җәфалау; борчу, азаплау.

**ГЛО'ССА** *лингв. юр.* — глосса (аңлашылмый торган сүзгә кульязманың эчендә яки аның читендә бирелгән аңлатма).

**ГЛОССА'РИЙ** *м. лингв.* — глоссарий (1. теге я бу тексттагы искергән һәм аз аңлашыла торган сүзләргә аңлатмалар җыентыгы — сүзлек; 2. законнар һәм юридик актларны аңлатып бирә торган җыентык).

**ГЛОТ** *м. простореч.* — 1. бирән, туймас тамак, гуж, ач күз; 2. *перен.* канечкеч.

**ГЛОТА'ТЕЛЬНЫЙ** — йоту ...-ы; йоту өчен хезмәт итә торган; *глотательные движения* — йоту хәрәкәтләре.

**ГЛОТА'ТЬ** *несов.* — 1. йоту; 2. *перен.* тыгыну, комсызланып ашау; 3. *перен. устар. книж.* (*истреблять, поглащать*) йоту, юкка чыгару; 4. *перен. разг.* (*много читать*) күп уку, комсызланып уку. ◇ **Глотать слова** — сүз йоту, сүзне йотып сөйләү, ашыгып сөйләү (ачык сөйләмәү). **Глотать слёзы** — күз яшен йоту.

**ГЛОТА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — йотылу.

**ГЛО'ТКА** *ж.* — 1. *анат.* йоткылык; 2. *разг. вульг.* тамак, бугаз; *схватить за глотку* — бугазына ябышу. ◇ **Здоровая глотка** *простореч.* — калын тавышлы, әче тавышлы. **Заткнуть глотку** *вульг. простореч.* — авызын ябу, авызын каплау (сөйләтмәү). **Драть глотку** *разг. вульг.* — акыру, акырып җырлау.

**ГЛОТНУ'ТЬ** *сов.* — йотып җибәрү, йоту (бер тапкыр).

**ГЛОТО'К** *м.* — 1. (*проглатывание*) йоту; 2. (*количество проглатываемого*) йотым, бер йотым.

**ГЛО'ТОЧНЫЙ** — йоту ...-ы; *глоточное отверстие* — йоту юлы.

**ГЛОТТОГОНИ'ЧЕСКИЙ** — глоттогония ...-ы; *глоттогонический процесс* — глоттогония процессы.

**ГЛОТТОГО'НИЯ** *ж. мн.* нет, *лингв.* — глоттогония (телнең килеп чыгуы).

**ГЛО'ХНУТЬ** *несов.* — 1. (*терять слух*) чукраклану, саңгыраулану; 2. (*о звуках*) акрыная бару, тына бару; 3. (*о саде*) томалану, кибү, корып ташландык хәлгә килү; 4. *перен.* (*о городе*) сүнә бару, җансызлану.

**ГЛУБИНА'** *ж.* — 1. тирәнлек; *глубина моря* — диңгезнең тирәнлеге; 2. *только ед.* түр, эчкәре; *в глубине зала* — залның түрендә; 3. *только ед. перен.* тирәнлек; *глубина чувств* — хисләренең тирәнлеге. ◇ **В морских глубинах** — диңгез төпләрендә. **В глубине души** — йөрәктә, йөрәк түрендә, күңел түрендә, күңелдә. **Из глубины души** — йөрәктән, чын күңелдән. **В глубине веков** — бик борынгыда, бик борынгы заманда. **Из глубины веков** — борын-борыннан, бик борынгыдан. **В глубине района** — районның ерак почмагында. **В глубине леса** — урман уртасында.

**ГЛУБИ'НКА** *ж.* — глубинка, эчкәре пункт (тимер юлдан, су юлларыннан ерак урнашкан ашлык тапшыру пункты — эчкәре пункт).

**ГЛУБИ'ННЫЙ** — 1. тирәнлек ...-ы; тирәндәге, тирәннән ...; *глубинная бомба* — тирәнлек бомбасы; *глубинный лов* — тирәннән тоту (мәсәлән, балыкны); 2. эчкәре; *глубинный пункт* — эчкәре пункт; *глубинные районы* — эчкәре районнар. ◇ **Глубинные мысли** — эчке фикерләр (уйлар).

**ГЛУБО'КИЙ** — 1. тирән; 2. эчкәре, эчкәреге, ерак; *глубокий тыл* — ерак тыл. ◇ **Глубокая ночь** — төн уртасы, җиде төн уртасы. **Глубокая осень** — кара көз (көзнең соңгы көннәре). **Глубокая тайна** — тирән сер, эчке сер. **Глубокая старость** — үтә картлык. **Глубокая печаль** — тирән кайгы. **Глубокий мыслитель** — тирәнтен фикерләүче, фикер йөртүче, зур фикер иясе. **Держать в глубокой тайне** *перен.* — тирән сер итеп саклау. **Глубокая разведка** *воен.* — дошманның ерак тылына разведка ясау. **Глубокие переживания** — тирән кичерешләр. **Питать глубокое уважение** — бик нык ихтирам итү. **Глубокая зима** — кыш уртасы.

**ГЛУБО'КО'** *нареч.* — 1. тирән, тирәнтен, тирән итеп, тирәндә, тирәнлектә; *глубоко вырыть яму* — тирән итеп чокыр казу; 2. бик нык, тирәнтен; *он его глубоко уважает* — ул аны бик нык ихтирам итә; *глубоко переживать* — бик нык кайгыру; 3. *безл. в знач. сказ.* тирән; *здесь очень глубоко* — монда бик тирән.

**ГЛУБОКОВО'ДНЫЙ** — 1. тирән судагы, тирән суларда яши торган, тирән су...-ы; *глубоководные рыбы* — тирән суларда яши торган балыклар; 2. тирән сулы, җитәрлек тирәнлектәге; *глубоководные реки* — тирән сулы елгалар.

**ГЛУБОКОМЫ'СЛЕННО** *нареч.* — тирән уйлап, тирәнтен уйлап.

**ГЛУБОКОМЫ'СЛЕННЫЙ** — 1. төпле, тирән фикерле, тирән мәгънәле, тирән уйлы; *глубокомысленные замечания* — тирән мәгънәле искәртүләр; *глубокомысленный человек* — тирән уйлы, тирән фикерле кеше; 2. (*серьёзный*) җитди, төпле.

**ГЛУБОКОМЫ'СЛИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. тирәнтен аңлау, төпле фикердә булу, тирән фикерлелек; 2. тирән мәгънәлелек.

**ГЛУБОКОУВАЖА'ЕМЫЙ** — кадерле, хөрмәтле.

**ГЛУБОЧА'ЙШИЙ** — 1. гаять тирән, бик тирән; *глубочайший колодец* — бик тирән кое; *глубочайшее презрение* — гаять тирән нәфрәт; 2. бик зур; гаять зур; *глубочайшее почтение* — гаять зур ихтирам (хөрмәт).

**ГЛУБЬ** *ж. мн.* нет, *книж. обл.* — к. глубина 1, 2.

**ГЛУБЬЕВО'Й** *спец.* — тирәнлектә..., тирән урыннарда ...; *глубьевой лов* — тирән урыннарда балык тоту.

**ГЛУМИ'ТЬСЯ** *несов.* — мыскыл итү, мәсхәрәләү.

**ГЛУМЛИ'ВЫЙ** *разг. устар.* — 1. (*о человеке*) мыскылларга (хурларга) яратучан, мәсхәрәләүчән; 2. (*о речах, словах*) мыскыллау ...-ы, хурлау ...-ы, мәсхәрәләү ...-ы; *глумливые речи* — мыскыллау сүзләре, мәсхәрәләү сүзләре.

**ГЛУПЕ'ТЬ** *несов. разг.* — аңгыралану, ахмаклану, тинтәкләнү, юләрләнү.

**ГЛУПЕ'Ц** *м.* — аңгыра, юләр, ахмак, тинтәк, сантый.

**ГЛУПИ'ТЬ** *несов. разг. фам.* — ахмаклыклар эшләү, мәгънәсез сүзләр сөйләү.

**ГЛУ'ПО** *нареч.* — 1. ахмакларча, юләрсыман, аңгыраларча; ахмаксыман; *он выглядел глупо* — ул ахмаксыман булып күренә иде; 2. *безл. в знач. сказ.* ахмаклык; *глупо так волноваться из-за пустяка* — юк-бар өчен алай борчылу ахмаклык ул.

**ГЛУПОВА'ТЫЙ** — юләрсымак, тилесыман, тилерәк, тинтәгрәк, аңгырарак; миңгерәүрәк, сантыйрак, тиле-миле.

**ГЛУ'ПОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* ахмаклык, тинтәклек, юләрлек, аңгыралык, сантыйлык; 2. *только мн. разг.* ахмаклыклар, ахмак сүзләр (эшләр, нәрсәләр); *брось эти глупости* — ташла бу ахмаклыкларны; 3. *в знач. межд., разг. фам.* юк сүз; *глупости! никогда этому не бывать!* — юк сүз! бу һичкайчан булмаячак!

**ГЛУ'ПЫЙ** — 1. (*слабоумный*) аңгыра, ахмак, миңгерәү, томана; 2. төпсез, мәгънәсез, акылсыз, ахмакларча...; *глупое поведение* — (үзеңне) ахмакларча тоту; *глупая затея* — акылсыз эш; *глупая книга* — мәгънәсез китап; 3. ахмак, акылга утырмаган, акыл кермәгән, акылсыз, беркатлы; *глупый ребёнок* — акыл кермәгән бала; *глупый щенок* — ахмак көчек.

**ГЛУПЫ'Ш** *м. разг.* — юләрем (балаларга сөеп әйтелә).

**ГЛУХА'РЬ** *м. зоол.* — 1. суер, урман тавыгы; 2. *разг. шутл.* (*о человеке*) чукрак, саңгырау; 3. *спец.* (*род винта*) зур винт, зур шөреп.

**ГЛУ'ХО** *нареч.* — тонык, талгын; тонык тавыш белән, талгын тавыш белән. ◇ **Об этом пишут глухо** — бу турыда ачык язмыйлар.

**ГЛУХОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — начар ишетү, колакка катылык.

**ГЛУХОВА'ТЫЙ** — 1. (*о человеке*) чукраграк, саңгыраурак, колакка катырак; 2. (*о голосе*) тоныграк; 3. (*о местности*) аулаграк, тынрак.

**ГЛУХО'Й** — 1. чукрак, саңгырау, колакка каты; *глухой старик* — чукрак карт; 2. *в знач. сущ.* чукрак (кеше); 3. *только крат. формы перен.* игътибарсыз; ишетми(м, сең), колак салмый(м, сың), игътибарсыз калдыра(м, сың); *он глух к моим мольбам* — ул минем ялваруларымны ишетми; 4. тонык, талгын; *глухой голос* — тонык тавыш; 5. аулак, тын, тыныч, караңгы, жансыз, хәрәкәтсез; *глухой уголок* — тын (аулак) урын; 6. *перен. книж.* ишетелеришетелмәс, әчтән генә...; *глухой ропот* — эчтән генә сукрану; 7. ташландык; *глухой сад* — ташландык бакча; *глухая тропинка* — ташландык сукмак. ◇ **Глухая стена** — тоташ стена, тәрәзәсез стена. **Глухое окно** — сукыр тәрәзә. **Глухие ворота** — тоташ капка. **Рубашка с глухим воротом** — ябык якалы күлмәк. **Глухая ночь** — кара төн, җиде төн уртасы. **Глухой согласный** *лингв.* — саңгырау тартык аваз. **Глухая крапива** — сукыр кычыткан. **Глухой лес** — кара урман. **Глухая тетеря** — чукрак (кеше турында).

**ГЛУХОНЕМО'Й** — чукрак-телсез; *он глухонемой* — ул чукрак-телсез; *глухонемой ребёнок* — чукрак-телсез бала.

**ГЛУХОНЕМОТА'** *ж. мн.* нет, *книж. спец.* — чукрак-телсезлек.

**ГЛУХОТА'** *ж. мн.* нет — 1. чукраклык, саңгыраулык; 2. *перен. книж.* ишетмәү, игътибар итмәү, колак салмау; игътибарсызлык; чукраклык; *душевная глухота* — рухи чукраклык.

**ГЛУШИ'ТЕЛЬ** *м.* — 1. *тех.* томалагычкиметкеч (тавышны); 2. *перен.* ирек бирмәүче, томалаучы, басучы, буучы; *глушитель критики* — тәнкыйтьне буучы, тәнкыйтькә ирек бирмәүче.

**ГЛУШИ'ТЬ** *несов.* — 1. миңрәтү; *глушить рыбу* — балыкны миңрәтү; 2. (*не давать расти*) томалау, каплау, басу, басып китү; 3. томалау; *глушить звук* — тавышны томалау; 4. сүндерү, томалау; *глушить самовар* — самоварны сүндерү (томалау); 5. *перен.* томалау, басу, буу, ирек бирмәү; *глушить инициативу* — инициативаны буу. ◇ **Глушить мотор** — моторны сүндерү (туктату).

**ГЛУШЬ** *ж. мн.* нет — караңгы почмак, аулак почмак, тын почмак, аулак урын, тын урын (культура үзәгеннән һәм кешеләрдән ерак урын).

**ГЛЫ'БА** *ж.* — кантар; зур кисәк; *каменная глыба* — зур таш кисәге; *глыба льда* — зур боз кисәге.

**ГЛЫБООБРА'ЗНЫЙ** *книж.* — кантарсыман.

**ГЛЫБОДРО'Б, ГЛЫБОДРОБИ'ТЕЛЬ** *м. с.-х.* — кантар ваткыч.

**ГЛЮ'КАТЬ** *несов. обл.* — горгылдау, коркылдау (күркә турында).

**ГЛЮКО'ЗА** *ж. хим.* — глюкоза (виноград шикәре).

**ГЛЯДЕ'ЛКИ** *ед.* нет, *простореч. разг. фам. пренебр.* — бәбәкләр (күзләр мәгънәсендә).

**ГЛЯДЕ'ТЬ** *несов.* — 1. (*смотреть*) карау, карап тору; 2. күзәтү, күз-колак булу; *глядеть за ребёнком* — балага күз-колак булу; 3. карау; *окна нашего дома глядят на улицу* — безнең өйнең тәрәзәләре урамга карый; 4. *перен.* күренеп тору, күренү; *из-за туч глядела луна* — болытлар арасыннан ай күренеп тора иде; 5. карау, үрнәк алу; *что тебе глядеть на них* — нәрсә сиңа аларга карарга, нәрсә сиңа алардан үрнәк алырга; 6. *разг.* булып күренү,...-га охшау; *глядеть героем* — герой булып күренү; 7. *просто-*

*реч.* карау, эзләү; *я глядел его в толпе, но не нашёл* — мин аны халык арасыннан карадым (эзләдем), ләкин тапмадым. ◇ **На ночь глядя** — төнгә каршы. **Того (и) гляди** — кара да тор, көт тә тор, менә карап тор; *того и гляди начнётся дождь* — менә көт тә тор, яңгыр ява башлар. **Иди, куда глаза глядят** *разг.* — дүрт ягың кыйбла, теләсәң кая кит. **Глядеть сквозь пальцы** — бармак аша карау, әһәмият бирмәү. **Глядеть в оба** — сак булу, абай булу, алны-артны карау. **Не глядел бы или глаза б (мои) не глядели** *разг.* — күрәсем дә килми. **Не глядел бы на свет (божий)** *разг.* — бер көн дә тормас идем. **Глядеть правде в глаза** — дөреслектән курыкмау.

**ГЛЯДЕ'ТЬСЯ** *несов.:* **глядеться в зеркало** — көзгегә карау; **месяц глядится в речку** — айның шәүләсе суга төшкән.

**ГЛЯДЬ** *межд. разг.* — карасам, карасак; *глядь, он идёт* — карасам (карасак) ул килә; *глядь, время-то прошло* — карасак, вакыт үтеп тә киткән.

**ГЛЯ'НЕЦ** *м. мн.* нет — ялтыравык; *глянец потускнел* — ялтыравыгы тоныкланган. ◇ **Навести глянец** — ялтырату.

**ГЛЯ'НУТЬ** *сов. однокр. разг.* — карау, карап алу, карап кую, күз төшереп алу, күз салып алу.

**ГЛЯНЦЕВА'ТЬ** *несов. спец.* — ялтырату; шомарту.

**ГЛЯНЦЕВИ'ТЫЙ** — ялтыравыклы; *глянцевитая бумага* — ялтыравыклы кәгазь.

**ГЛЯ'НЦЕВЫЙ** — ялтыравыклы.

**ГМ** *межд. разг.* — һе, алай икән (шикләнү, ышанмау).

**ГНАТЬ** *несов.* — 1. (*прогонять*) куу, куып җибәрү; 2. (*выгонять*) куып чыгару; 3. куу, әйдәү, куып алып бару, куып алып килү; *гнать коров на пастбище* — сыерларны көтүгә куу; 4. куу, куалау, ашыктыру, чаптыру; *гнать лошадь* — атны куалау (чаптыру); *гнать с работой* — эшне ашыктыру; 5. *книж.* (*притеснять*) эзәрлекләү, эзәрләү, кысу; 6. эзәрлекләү, куып бару; *гнать зверя* — җәнлекне куып бару; 7. куу, чыгару, табу; *гнать дёготь* — дегет куу. ◇ **Гони монету** — чыгар акчаңны, бир акчаңны. **Гнать лес** — сал агызу. **Не гони лошадь кнутом, а гони овсом** — атны чыбыркы белән кума, солы белән ку.

**ГНА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. куып бару; *гнаться за отступающим противником* — чигенүче дошман артыннан куып бару; 2. куу, артыннан куу; *империалисты гонятся за максимальной прибылью* — империалистлар максималь табыш артыннан куалар; 3. *страд.* куылу, чыгарылу; *спирт гонится из картофеля* — спирт бәрәңгедән куыла. ◇ **Гнаться за двумя зайцами** — ике көймәнең койрыгын тоту.

**ГНЕВ** *м. мн.* нет — ачу.

**ГНЕ'ВАТЬСЯ** *несов.* — ачулану, ачу кабару.

**ГНЕВИ'ТЬ** *несов.* — ачуландыру, ачу китерү, ачуын кабарту.

**ГНЕВЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тиз ачулану, тиз ачуланучанлык.

**ГНЕВЛИ'ВЫЙ** *разг. устар.* — тиз ачуланучан.

**ГНЕ'ВНО** *нареч.* — ачуланып, ачу белән.

**ГНЕ'ВНЫЙ** — ачулы; *гневный взгляд* — ачулы караш.

**ГНЕДО'Й** — туры (ат төсе).

**ГНЕДОКА'РИЙ** — кара туры (ат төсе).

**ГНЕДОЧА'ЛЫЙ** — туры бурлы (ат төсе).

**ГНЕЗДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. оялау, оя ясау; *грачи гнездятся на деревьях* — кара каргалар агач башына оялый; 2. *перен.* урнашу; *хижины гнездились по склону горы* — алачыклар тау итәгенә урнашканнар иде; 3. *перен.* тулу, тулып яту; *гнездятся какие-то мысли в голове* — башымда әллә нинди уйлар тулып ята.

**ГНЕЗДО'** *ср.* (*мн.* гнёзда) — 1. оя; *птичье гнездо* — кош оясы; 2. куыш; *своё гнездо* — үз куышым; 3. (*выводок животных, группа ягод*) бер оя; 4. (*углубление, впадина*) уем, уемтык, чокыр; 5. *воен.* оя, чокыр; *пулемётное гнездо* — пулемёт чокыры. ◇ **Гнездо слов** — тамырдаш булган сүзләр. **Свить себе гнездо** — 1. оялау; 2. тормыш кору. **Гнездо заразы** — йогыш чыганагы.

**ГНЕЗДОВО'Й** — оялап, оя-оя итеп; *гнездовая посадка* — оялап утырту (үсемлекләрне).

**ГНЁЗДЫШКО** *ср.* — кечкенә оя.

**ГНЕСТИ'** *несов.* — 1. борчу, җәфалау, интектерү; *меня гнетут мрачные мысли* — мине күңелсез уйлар җәфалый; 2. *тех.* сыгу, сыгып чыгару; *подсолнечное масло гнетут прессом* — көнбагыш маен пресс белән сыгып чыгаралар; 3. *устар.* (*пригибать своей тяжестью*) ию, бөгү.

**ГНЁТ** *м. мн.* нет — 1. изү, кысу; *колониальный гнёт* — колониаль изү; 2. *тех.* пресс; эскәнҗә; 3. *обл. с.-х.* бастырык.

**ГНЕТУ'ЩИЙ** — 1. изүче, кысучы; 2. *книж.* авыр, караңгы, күңелсез; *гнетущие мысли* — авыр (караңгы, күңелсез) уйлар.

**ГНИ'ДА** *ж.* — 1. серкә (бет серкәсе); 2. *бран. простореч.* әшәке кеше, кабахәт кеше.

**ГНИЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет. *книж.* — 1. черү; 2. *перен.* черөп таркалу, әхлакый бозылу; *гниение буржуазной культуры* — буржуаз культураның череп таркалуы.

**ГНИЛЕ'Ц** *м. мн.* нет, *спец.* — 1. *зоол.* черек авыруы (умарта корты балаларында); 2. (*плесень*) күгәрек (черетә торган күгәрек).

**ГНИЛО'Й** — 1. черек, черегән; *гнилое дерево* — черек агач; 2. (*испорченный, затхлый*) бозылган, сасыган, исләнгән; 3. *перен.* юеш, яңгырлы; *гнилая погода* — юеш һава; 4. *книж. перен.* принципсыз, черек; *гнилой либерализм* — принципсыз (черек) либерализм; 5. (*морально разложившийся*) череп таркалган.

**ГНИ'ЛОСТНЫЙ** — 1. черетә торган, черткеч; *гнилостные бактерии* — череткеч

бактерияләр; 2. *книж.* черек, бозык; *гнилостный запах* — черек исе, бозык ис.

**ГНИ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — череклек; бозыклык; *гнилость капитализма* — капитализмның череклеге.

**ГНИЛУ'ШКА** *ж. разг.* — черек агач кисәге; черек (әйбер).

**ГНИЛЬ** *ж. мн.* нет — 1. *собир.* черек, черек-чарык, черегән әйберләр; 2. *перен. презр.* череклек, идея-әхлак ягыннан бозыклык.

**ГНИЛЬЁ** *ср. мн.* нет — к. гниль 1.

**ГНИЛЬЦА'**: с гнильцой *разг.* — 1. чери башлаган, черекле, бозыла башлаган; 2. *перен.* бозыграк; *он человек с гнильцой* — ул бозыграк кеше.

**ГНИТЬ** *несов.* — 1. черү, таркалу; *сено гниёт* — печән чери; 2. *перен. книж.* черең таркалу; *капиталистический мир гниёт* — капиталистик дөнья череп таркала.

**ГНИЮ'ЧИЙ** — черүчән.

**ГНОЕВИ'ДНЫЙ** *спец.* — эренсыман.

**ГНОЕРО'ДНЫЙ** — эренләтә торган; эрен ...-ы; *гноеродные бактерии* — эрен бактерияләре.

**ГНОЕТОЧИ'ВЫЙ** — эренле, эрен килә торган; *гноеточивая рана* — эренле яра (эрен агып тора торган яра).

**ГНОИ'ТЬ** *несов.* — черетү; *дождь гноит сено* — яңгыр печәнне черетә; *гноить в тюрьме* — төрмәдә черетү.

**ГНОИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. эренләү; үлекләү; *рана гноится* — яра эренли; 2. *страд.* черетелү; *навоз гноится в особых кучах* — тирес махсус өемнәрдә черетелә.

**ГНО'ИЩЕ** *ср. книж. устар.* — чүплек, чүплек башы.

**ГНОЙ** *м. мн.* нет — эрен, үлек.

**ГНОЙНИ'К** *м.* — 1. *мед.* эрен җыелган урын, эренләгән урын; 2. *перен.* череклек, череклек чыганагы.

**ГНО'ЙНЫЙ** — эренле, үлекле; эрен җыю ... -ы; *гнойная рана* — эренле яра; *гнойный процесс* — эрен җыю процессы.

**ГНОМ** *м. миф.* — гном (Көнбатыш Европа мифологиясе буенча җир астындагы хәзинәне саклап тора торган кәрлә кеше).

**ГНОСЕОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *филос.* — гносеологик, гносеология ..-ы; *гносеологический метод* — гносеологик метод.

**ГНОСЕОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *филос.* — гносеология (танып белү теориясе).

**ГНОСТИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — гностицизм (христиан диненең беренче чорында дини-философик агым).

**ГНУС** *м. мн.* нет, *обл.* — 1. зарарлы бөҗәк; 2. *вульг.* хәшәрәт, кабахәт (кеше турында).

**ГНУСА'ВИТЬ** *несов.* — тыңкышлану, борын белән сөйләү.

**ГНУСА'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тыңкышлык.

**ГНУСА'ВЫЙ** — тыңкыш.

**ГНУСИ'ТЬ** *несов. разг.* — к. гнусавить.

**ГНУСЛИ'ВЫЙ** — к. гнусавый.

**ГНУ'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет — кабахәтлек.

**ГНУ'СНЫЙ** — кабахәт, чирканыч, түбән.

**ГНУСЬ** *ж. мн.* нет, *простореч. презр.* — кабахәтлек.

**ГНУ'ТЫЙ** — 1. бөгелгән; бөгеп ясалган; 2. *разг. фам.* кәкре; *гнутые ноги* — кәкре аяк (камыт аяк).

**ГНУТЬ** *несов.* — 1. бөгү; *гнуть дугу* — дуга бөгү; 2. ию, бөгү; *буря гнёт деревья* — давыл агачларны ия; 3. бору, каеру; *я вижу, куда он гнёт* — мин аның кая таба борганын сизеп торам. ◇ **Гнуть горб (спину)** — бөкресе чыкканчы эшләү. **Гнуть шею (спину)** — баш ию, йөз суы түгү. **Гнуть свою линию** — үзенекен итү, үз дигәнен эшләү, үз сүзен итү, үзенекен сукалау.

**ГНУ'ТЬСЯ** *несов.* — бөгелү, нелү, сыгылу.

**ГНУША'ТЬСЯ** *несов.* — 1. (*брезговать*) чиркану, җирәнү, нәфрәтләнү; 2. (*чуждаться*) хурлык дип санау, гарьлек дип санау; кимчелек дип санау.

**ГОБЕЛЕ'Н** *м.* — гобелен (бизәкләп эшләнгән стена ковёры).

**ГОБОИ'СТ** *м. муз.* — гобоист (гобойда уйнаучы).

**ГОБО'Й** *м. муз.* — гобой (курайсыман музыка коралы).

**ГОВА'РИВАТЬ** *многокр. устар. разг.* — әйткәләү, сөйләштергәләү.

**ГОВЕ'ЛЬЩИК** *м.*, **ГОВЕ'ЛЬЩИЦА** *ж. разг. церк.* — ураза тотучы.

**ГОВЕ'ТЬ** *несов. церк.* — 1. ураза тоту; 2. *перен.* ач тору.

**ГО'ВОР** *м.* — 1. *только ед.* сөйләшү, сөйләшкән тавыш; 2. *перен. поэт.* (*шум, гул*) гөрелдәгән тавыш; 3. *только ед.* (*пересуды, молва*) хәбәр, сүз, имеш-мимеш, гайбәт; 4. (*особенности речи*) сөйләү үзенчәлеге, әйтелеш үзенчәлеге; 5. *лингв.* сөйләш; *местный говор* — җирле сөйләш.

**ГОВОРИ'ТЬ** *несов.* — 1. сөйләшү, сөйләшә белү; *ребёнок ещё не говорит* — бала сөйләшә белми әле; *я свободно говорю по-русски* — мин русча яхшы сөйләшәм (сөйләшә беләм); 2. сөйләү, әйтү; *говорить правду* — дөресен сөйләү; *говорить по-татарски* — татарча сөйләү; 3. әйтү; *он говорит об этом в 1 томе своей книги* — ул бу турыда китабының 1 томында әйтә; 4. сөйләшү; *я с ним говорил* — мин аның белән сөйләштем; 5. *перен.* белдерү, күрсәтеп тору, әйтеп тору; раслау; белгертеп тору, күренеп тору; *тучи говорят о приближающейся буре* — болытлар давыллы яңгыр буласын күрсәтеп торалар; *все факты говорят о том, что он хороший работник* — бөтен фактлар аның яхшы работник булуын раслыйлар; *в нём говорит старый рабочий* — аның карт эшче икәне беленеп тора (күренеп тора); *твои глаза говорят об этом* — синең күзләрең үк моны

әйтеп тора; **6.** дию, әйтү; *что он говорит?* — ул нәрсә ди? ◇ **Что и говорить** — сөйләп тә торасы юк инде. **Нечего говорить** *разг.* — әйтәсе дә юк, сөйләп тә торасы юк. **Иначе говоря** — башкача әйткәндә. **Говорит сама за себя** *разг.* — үзеннән-үзе күренеп тора. **Собственно говоря** — ачыктан ачык итеп әйткәндә. **По правде говоря** — дөресен әйткәндә. **Как говорят,** или **говорят, что** *разг.* — диләр, дип сөйлиләр. **Не говорите** *разг. фам.* — сөйләмә дә инде, әйтмә дә инде. **Не говоря худого слова** *разг. шутл.* — берни дә әйтмәстән, кинәт. **Не говоря уже** — исәпкә алмаганда да. **Говорит в нос** — тыңкышланып сөйли, борын аша сөйли. **Ребёнок начал говорить** — баланың теле ачылды. **Ничего не говорящие слова** — буш сүзләр. **Он не говорит от рождения** — ул тумыштан телсез.

**ГОВОРИ'ТЬСЯ** *несов.* — әйтелү, сөйләнү, диелү; *в письме говорится так* — хатта болай диелгән. ◇ **Комментарии, как говорится, излишни** — моны аңлатып торасы да юк инде.

**ГОВОРЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — сүзчәнлек, күп сөйләүчәнлек.

**ГОВОРЛИ'ВЫЙ** — **1.** сүзчән, күп сөйләүчән; **2.** *перен. книжн.* чылтырап аккан (ага торган); *говорливый ручеёк* — чылтырап аккан чишмә.

**ГОВОРНО'Й** *лит. спец.* — сөйләү теленә хас (стиль), сөйләү телендәгечә язылган (шигырь).

**ГОВОРО'К** *м. разг.* — сөйләү (сөйләү манеры); *слащавый говорок* — төче теллеләнеп сөйләү; *быстрый говорок* — кызу сөйләү.

**ГОВОРУ'Н** *м.*, **ГОВОРУ'НЬЯ** *ж.* — тел бистәсе.

**ГОВЯ'ДИНА** *ж. мн.* нет — сыер ите.

**ГОВЯ'ЖИЙ** — **1.** сыер итеннән пешерелгән; *говяжья котлета* — сыер итеннән пешерелгән котлет; **2.** сыер ...-ы; *говяжье сало* — сыер мае (туңмай).

**ГОГ** и **ГОГА: гог и магог, гога и магога, гог-магог, гога-магога** *разг. устар.* — яэҗүҗ-мәэҗүҗ, куркынычлы, дәһшәтле.

**ГО'ГОЛЬ** *м. зоол.* — гоголь, ала чумгалак. ◇ **Ходить гоголем** *разг. ирон.* — фырт йөрү, көязләнеп (купшыланып) йөрү.

**ГО'ГОЛЬ-МО'ГОЛЬ** *м. мн.* нет — гоголь-моголь (йомырка сарысын шикәр белән, кайчакта ром белән дә тугылап хәзерләнгән татлы ашамлык).

**ГОГОТА'ТЬ** *несов.* — **1.** (*о гусях*) гаңгылдау, гаңгылдап кычкыру, кыйгаклау, кыйгак-кыйгак кычкыру; **2.** (*хохотать*) хахылдау, шаркылдап көлү.

**ГОД** *м.* (*мн.* годà, гóды) — **1.** ел; *учебный год* — уку елы; *в прошлом году* — узган ел, былтыр; **2.** яшь; *ему уже три года* — ул инде өч яшьтә; **3.** *только мн.* чаклар; *молодые годы* — яшь чаклар. ◇ **В этом году** — быел. **Без году неделя** *разг. шутл.* — аз гына, бик аз. **Круглый год** — ел буе, ел буена. **Из года в год** — ел саен, елдан-ел. **Год от году** — елдан елга. **Чёрный год** — авыр ел.

**ГОДА'МИ** *нареч.* — **1.** (*по целым годам*) еллар буена; **2.** кайбер елларда; *не только годами, а всегда будет хороший урожай* — кайбер елларда гына түгел, бәлки һәр елны яхшы уңыш булачак.

**ГО'ДИК** *м.* — ел, бер ел.

**ГОДИ'НА** *ж.* — **1.** *книжн.* еллар, заман; *година испытаний* — сынау еллары; *година войны* — сугыш еллары; **2.** *поэт. устар.* ел; *каждую годину* — һәр елны.

**ГОДИ'ТЬ** *несов. разг. шутл.* — көтү, көтеп тору; *сказано: погоди, ну, и годи* — көт дигәч көт инде.

**ГОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — ярау, яраклы булу; *эти сапоги не годятся мне* — бу итек миңа ярамый. ◇ **Не годится** *разг.* — ярамый, килешми, яхшы түгел.

**ГОДИ'ЧНЫЙ** — **1.** бер еллык; *годичный испытательный срок* — бер еллык сынау срогы; **2.** еллык; *годичный отчёт* — еллык отчёт; *годичные кольца* — еллык балдаклар, яшь балдаклары (агачта).

**ГО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — яраклылык, яраклы булу; *годность зерна для посева* — орлыкның чәчү өчен яраклылыгы.

**ГО'ДНЫЙ** — яраклы, ярарлык, эшкә киләрлек; *годный для военной службы* — хәрби хезмәткә яраклы.

**ГОДОВА'ЛЫЙ** *разг.* — бер яшьлек; *годовалый ребёнок* — бер яшьлек бала.

**ГОДОВО'Й** — еллык, бер еллык; *годовой отчёт* — еллык отчёт; *годовой доход* — еллык доход.

**ГОДОВЩИ'НА** *ж.* — еллык; еллык бәйрәм; *38 годовщина Великой Октябрьской социалистической революции* — Бөек Октябрь социалистик революциясенең 38 еллыгы.

**ГОДО'К** *м.* — ел, бер ел.

**ГОДО'ЧЕК** *м.* — ел.

**ГОЛ** *м. спорт.* — гол (**1.** спорт уенында тупны кертү өчен таяк утыртып яки сызып билгеләнгән капка; **2.** тупны шул капкага кертеп отылган очко).

**ГОЛА'ВЛЕВЫЙ, ГОЛОВЛЁВЫЙ** — кушбаш балыгыннан (пешерелгән); кушбаш..-ы; *голавлевая икра* — кушбаш икрасы.

**ГОЛА'ВЛЬ, ГОЛО'ВЛЬ** *м. зоол.* — кушбаш (балык).

**ГОЛГО'ФА** *ж.* — **1.** голгофа (Иерусалим тирәсендә җәзалау урыны; инҗил буенча анда Гайса баганага кадаклап үтерелгән имеш); **2.** *перен.* җәфалану чыганагы, җәфа чигү урыны.

**ГОЛЕНА'СТЫЙ** *разг.* — озын ботлы, озын аяклы, озын сыйраклы; *голенастая цапля* — озын аяклы челән.

**ГОЛЕНИ'ЩЕ** *ср.* — куныч, балтыр (аяк киемендә).

**ГО'ЛЕНЬ** *ж. анат.* — балтыр, сыйрак.

**ГОЛЁХОНЬКИЙ** *разг.* — яп-ялангач, шәпшәрә.

**ГОЛЕ'Ц** *м. зоол.* — **1.** сагалак (юка тиреле тәңкәсез балык); **2.** ялангач балык (Төньяк диңгез балыгы).

**ГОЛИА'Ф** *м.*— голиаф (1. библия әкияте буенча гаять зур кеше; 2. *перен.* гигант, зур гәүдәле кеше).

**ГОЛИЗНА'** *м. мн.* нет — ялангачлык, шәрәлек.

**ГОЛИ'К** *м. обл.*— себерке, ындыр себеркесе (яфраксыз себерке).

**ГОЛИ'НКА** *ж. обл.*— корыган агач, шәрә агач, яфраксыз агач.

**ГОЛИ'ЦА** *ж. простореч. обл.*— астарсыз күн бияләй.

**ГОЛКИ'ПЕР** *м. спорт. устар.*— к. вратарь.

**ГОЛЛА'НДЕЦ** *м.*—голландияле, Голландия кешесе.

**ГОЛЛА'НДКА** I *ж.*— голландияле хатынкыз.

**ГОЛЛА'НДКА** II *ж.*— галанка (мич).

**ГОЛЛА'НДСКИЙ** — голландский, Голландия ...-ы; *голландский сыр* — голландский сыр; *голландское правительство* — Голландия хөкүмәте.

**ГОЛЛА'НДЦЫ** *мн.* (*ед.* голландец)— голландиялеләр, Голландия халкы.

**ГОЛОВА'** *ж.*— 1. баш; *голова болит* — баш авырта; *сто голов овец* — йөз баш сарык; *голова сахара* — бер баш шикәр; *голова пехотной колонны* — пехота колоннасының башы; 2. *перен. разг.* баш, башлык, хуҗа; *городской голова (дореволх.)* — шәһәр башлыгы; *сам себе голова* — үз-үзенә хуҗа. ◇ **Адамова голова** — баш сөяге (астына ике аркылы сөяк куеп ясалган баш сөяге рәсеме, электр тогы бәрү куркынычы булган урыннарда куела). **В головах, или в изголовьи** — баш очында. **В первую голову** — барыннан да элек, беренче чиратта. **Вымыть или намылить голову** *перен. разг. фам.*— шелтәләү, кыздыру, пешерү. **Голова в голову (двигаться)** *воен.*— типтигез саф булып (бару). **Повесить голову** — башны салындыру. **Закружилось в голове, закружилась голова** — баш(ым) әйләнде. **Из головы вон** — баштан чыккан, истән чыккан, онытылган. **Ломать голову** — баш вату. **О двух головах** —ике башлы кеше, тәвәккәл кеше. **С головой отдаться, или уйти** — баш белән чуму (берәр эшкә). **Выдать головой** — тотып бирү, тоттыру, серен ачу. **Как снег на голову (появиться)** — көтмәгәндә (килеп чыгу). **Разбить на голову** — тар-мар итү (сугышта). **С больной головы на здоровую** —ак эт бәласе кара этка (гаепне кешегә аудару). **Быть головой выше** *книжс.*— әлләникадәр югары тору (акыл ягыннан). **С головы до ног** — баштанаяк. **На голову (сыпаться, обрушиться)** — башка төшү. **Сломя голову** — җан-фәрманга, бөтен көче белән. **Голова идёт кругом** (*у кого*) — баш катты, баш катып бетте, баш әйләнеп бетте. **Ручаюсь головой** — башымны кисәргә бирәм. **Взять на свою голову**—үз өстенә алу. **Сложить голову** — баш кую, корбан булу.

**ГОЛОВА'СТИК** *м. зоол.*— чукмарбаш.

**ГОЛОВА'СТЫЙ** — зур башлы, тубал башлы.

**ГОЛОВЁНКА** *ж.*— кечкенә баш.

**ГОЛОВЁШКА** *ж. разг.*— кисәү, кисәү башы (янып бетмәгән агач кисәге).

**ГОЛО'ВКА** *ж.*— 1. кечкенә баш; 2. (*у винта, булавки*) баш, эшләпә; 3. баш; *головка лука* — бер баш суган; 4. *разг.* (*группа руководящих лиц*) житәкчеләр, башлыклар; 5. *только мн.* (*у сапог*) итек башы; (*у саней*) чана башы (чана табанының бөгелгән өлеше).

**ГОЛОВНО'Й** — 1. баш...-ы; *головной убор* — баш киеме; 2. алдынгы, алдан баручы, башлап баручы, башта баручы; *головной отряд* — алдан (башта) баручы отряд.

**ГОЛОВНЯ'** I *ж.*— к. головёшка.

**ГОЛОВНЯ'** II *ж. мн.* нет — кисәү, корымбаш, гөмбә (ашлыкларда авыру).

**ГОЛОВОКРУЖЕ'НИЕ** *ср.*— баш әйләнү.

**ГОЛОВОКРУЖИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. баш әйләндергеч, баш әйләнерлек; *головокружительная высота* — баш әйләнерлек биеклек; 2. искитәрлек, бик зур; *головокружительный успех* — искитәрлек уныш.

**ГОЛОВОЛО'МКА** *ж. разг.*— башваткыч.

**ГОЛОВОЛО'МНЫЙ** —башваткыч, катлаулы, кыен, читен; *головоломный вопрос* — башваткыч мәсьәлә.

**ГОЛОВОМО'ЙКА** *ж. разг.*— каты шелтә, кыздыру, пешерү.

**ГОЛОВОРЕ'З** *м. разг. неодобр.*— башкисәр, юлбасар; җәнҗалчы; *фашистские головорезы* — фашист башкисәрләр.

**ГОЛОВОТЯ'П** *м. разг.*— юньсез, баш катыручы.

**ГОЛОВОТЯ'ПСКИЙ** — акылсыз, башкатыргыч; *головотяпское распоряжение* — башкатыргыч боерык.

**ГОЛОВОТЯ'ПСТВО** *ср. разг.* — баш катыру, юньсезлек.

**ГОЛО'ВУШКА** *ж. разг. поэт.* — баш, башкай. ◇ **Пропала моя головушка** — бетте баш, харап булдым. **Буйная головушка** — егет кеше, тәвәккәл кеше.

**ГО'ЛОД** *м. мн.* нет — 1. ачлык; 2. *перен.* кытлык; *книжный голод* —китап кытлыгы. ◇ **Голод мучил меня с утра** — иртәдән бирле ашыйсы килеп интектем. **Утолить голод** — тамак ялгап алу.

**ГОЛОДА'ТЬ** *несов.*— 1. (*испытывать голод*) ачыгу; 2. (*скудно питаться*) ачлытуклы тору, ачлы-туклы яшәү; 3. (*воздерживаться от употребления какой-н. пищи*) ашамый тору; 4. (*воздерживаться от пищи в знак протеста*) ач тору, ашамау.

**ГО'ЛОДНО** *нареч.*— ач, ачлы-туклы.

**ГОЛО'ДНЫЙ** — 1. ач; *голодный волк* — ач бүре; *на голодный желудок* — ач карынга; 2. ач, ачтан...; *голодная смерть* — ач үлем, ачтан үлү; 3. ачлы-туклы, житәржитмәс, ачлык...; ач...; *голодный паёк* — жи-

тәр-җитмәс паёк; *голодный год*—ачлык ел; *голодный край*—ач як. ◇ **Голодный тиф** — тимгелле тиф. **Голодная шерсть** — арык йон (озак вакыт ач торган сарыклардан алынган йон). **Сытый голодного не разумеет** — ач кадерен тук белми.

**ГОЛОДОВА'ТЬ** *несов. обл. простореч.*— к. голодать 1.

**ГОЛОДО'ВКА** *ж.*— **1.** голодовка, ашаудан баш тарту (протест йөзеннән); **2.** *обл. просторечь.* ачлык.

**ГОЛОДРА'НЕЦ** *м. просторечь. презр.*— хәерче, сәләмә киемле кеше.

**ГОЛОДУ'ХА** *ж.*: **с голодухи** *просторечь.*— ачлыктан, ачлы-туклы торудан.

**ГОЛОЛЕ'ДИЦА** *ж. мн.* нет — бозгалак, бозлавык, тайгалак, тайгаклык.

**ГОЛОНО'ГИЙ** *разг.* — **1.** ялан аяклы; **2.** шәрә аяклы; *голоногий страус* — шәрә аяклы страус.

**ГО'ЛОС** *м. (мн.* голоса́) — **1.** тавыш; *в один голос* — бертавыштан, беравыздан; **2.** *перен.* фикер, сүз; *нужно прислушиваться к голосу масс* — массаның фикеренә колак салырга кирәк; **3.** *перен. книж.* тавыш, сизем; *голос сердца* — күңел сиземе; *голос совести* — вөҗдан тавышы. ◇ **С голоса** — телдән; *ещё не умеющие читать дети учат стихи с голоса*— укый белми торган балалар шигырьләрне телдән өйрәнәләр. **Быть в голосе** — яхшы җырлау. **Поднять голос в защиту** *кого-н.*— берәүне яклап чыгу. **С чужого голоса** — кеше сүзе буенча, кеше фикерен кабатлап. **Плакать в голос** *просторечь.* — акырып елау. **Кричать в голос** *просторечь.*— акыру.

**ГОЛОСИ'НА** *ж.* — көчле тавыш, каты тавыш.

**ГОЛОСИ'СТЫЙ** — көчле тавышлы, матур тавышлы.

**ГОЛОСИ'ТЬ** *несов.*— **1.** такмаклап елау; **2.** *разг. фам.* акырып елау, үкереп елау; акыру.

**ГОЛОСЛО'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — дәлилсезлек, нигезсезлек.

**ГОЛОСЛО'ВНЫЙ** — нигезсез, дәлилсез, коры, фактларга нигезләнмәгән; *голословное обвинение* — нигезсез гаепләү.

**ГОЛОСНУ'ТЬ** *однокр. разг. фам.* — тавышка кую, тавышка куеп алу; тавыш бирү.

**ГОЛОСОВА'НИЕ** *ср.* — тавыш бирү. ◇ **Поставить на голосование** — тавышка кую.

**ГОЛОСОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— **1.** *(подать голос)* тавыш бирү, кул күтәрү; **2.** *(ставить на голосование)* тавышка кую.

**ГОЛОСОВО'Й** — **1.** тавыш ...-ы; *голосовые связки* — тавыш ярылары; **2.** *лингв.* тавышлы; *голосовые звуки* — тавышлы авазлар.

**ГОЛОСТЕ'БЕЛЬНЫЙ** — ялангач сабаклы, шәрә сабаклы; *голостебельные растения*— ялангач сабаклы үсемлекләр.

**ГОЛОУ'СЫЙ** *разг. фам. шутл.* — **1.** мыексыз, мыек чыкмаган; **2.** *перен.* яшь.

**ГОЛОШТА'ННИК** *просторечь. бран.*— **1.** сәләмә, йолкыш; **2.** *шутл.* штансыз (кечкенә бала турында).

**ГОЛОШТА'ННЫЙ** — хәерче, сәләмә, йолкыш.

**ГОЛУБЁНОК** *м. (мн.* голубя́та) — күгәрчен баласы.

**ГОЛУБЕ'ТЬ** *несов.* — **1.** күгелҗемләнеп күренү, күгелҗемләнеп тору, зәңгәрләнеп күренү, зәңгәрләнеп тору; *вдали голубело море* — ерактa диңгез күгелҗемләнеп тора иде; **2.** күк төскә керү, күгелҗемләнә бару, зәңгәрләнә бару; *небо голубеет* — күк йөзе зәңгәрләнә бара.

**ГОЛУБЕ'Ц** *м.*— к. голубцы.

**ГОЛУБИЗНА'** *ж. мн.* нет, *книж.*— күклек, зәңгәрлек; *голубизна глаз* — күзләренең зәңгәрлеге.

**ГОЛУБИ'КА** *ж. мн.* нет — күк җиләк (тоньякта сазлыкта үсә торган җиләк).

**ГОЛУБИ'НЫЙ** — **1.** күгәрчен ...-ы; *голубиный помёт* — күгәрчен тизәге; **2.** *устар.* юаш; *голубиный характер* — юаш характер.

**ГОЛУ'БИТЬ** *несов.*— иркәләү, сөю.

**ГОЛУБИ'ЦА** I *ж. книж. устар.*— **1.** к. голубка; **2.** саф, гыйффәтле (гадәттә кызлар турында).

**ГОЛУБИ'ЦА** II *ж. мн.* нет, *обл.*— к. голубика.

**ГОЛУ'БКА** *ж.* — **1.** *зоол. (птица)* ана күгәрчен; **2.** *разг. фам.* күгәрченкәй; *голубка ты моя* — күгәрченем син минем.

**ГОЛУБОВА'ТЫЙ** — күгелҗем, күксыман, зәңгәрсу.

**ГОЛУБОГЛА'ЗЫЙ** — зәңгәр күзле, күк күзле.

**ГОЛУБО'Й** — зәңгәр, күк; *голубое небо* — зәңгәр күк; *голубое озеро* — зәңгәр күл; *голубая рубашка* — күк күлмәк. ◇ **Голубая кровь** *устар. теперь ирон.*— аксөяк.

**ГОЛУБО'К** I *м.* — **1.** к. голубь; **2.** *просторечь.* к. голубчик.

**ГОЛУБО'К** II *м. бот.* — сужыяр, күгәрчен чәчәге.

**ГОЛУ'БУШКА** *ж. разг.*— к. голубка.

**ГОЛУБЦЫ'** *мн. (ед.* голубец) *кулин.*— голубцы (кәбестә яфрагына төреп пешерелгән ит, дөге h. б.).

**ГОЛУ'БЧИК** *м. разг.* — **1.** күгәрченем, күгәрченкәй; **2.** *ирон.* энекәш, егет, туганкай.

**ГО'ЛУБЬ** *м.*— күгәрчен.

**ГОЛУБЯ'ТИНА** *ж. разг.* — күгәрчен ите.

**ГОЛУБЯ'ТНИК** *м.*— **1.** *(любитель голубей)* күгәрчен асраучы; **2.** *зоол.* күгәрчен карчыгасы.

**ГОЛУБЯ'ТНЯ** *ж.*— күгәрчен оясы, күгәрчен кетәге.

**ГО'ЛЫЙ** — 1. ялангач, ялан; *не становись голыми ногами на пол* — яланаяк идәнгә басма; *(о дереве)* яфраксыз; 2. ачык; *голая степь* — ачык дала; 3. буш, коры; *голые стены* — буш стеналар; *спать на голом полу* — коры идәндә йоклау; 4. *разг.* шыр; *это не суп, а голая соль* — бу аш түгел, шыр тоз гына; 5. *разг.* коры; *голые цифры* — коры цифрлар гына. ◇ **Голый обман** — чеп-чи ялган. **Гол как сокол** — үзе дә ике күзе, шыр ялангач (бернәрсәсе юк). **Брать голыми руками** — җиңел генә алу, ансат кына алу. **Голая зима** — карсыз кыш. **С голыми руками** — буш кул белән. **Голая голова** — такыр баш. **Голой рукой не тронь** — сак бул.

**ГОЛЫТЬБА'** *ж. мн.* нет, *собир. устар.* — ярлылар, йолкышлар, ярлы-ябагай.

**ГОЛЫ'Ш** *м. разг.* — 1. *(о ребёнке* и т. п.*)* ялангач, шәрә; 2. *(кукла)* ялангач курчак; 3. *(камень)* шома, түгәрәк таш (уртача зурлыкта); 4. *обл.* ярлы, фәкыйрь.

**ГОЛЫ'ШКА** *разг. фам.* — к. голыш 1, 2.

**ГОЛЫШО'М** *нареч. разг.* — ялангач килеш, ялангач, шәрә килеш.

**ГОЛЬ** *ж. мн.* нет, *собир. разг. фам. устар.* — к. голытьба.

**ГО'ЛЬДЫ** *мн.* (*ед.* гольд) — гольдлар (Амур елгасының түбән агымында яшәүче нанай халкының элекке исеме).

**ГОЛЬЁ** *ср. мн.* нет — 1. шәрә тире (иләү өчен әзерләнеп куелган тире); 2. эче-башы (баш-аяк, үпкә-бавыр, эчәк).

**ГОЛЬЁМ** *нареч. простореч.* — үзен генә, саф килеш, бернәрсә катыштырмыйча.

**ГОЛЬФСТРИ'М, ГОЛЬФШТРЕ'М** *м.* — Гольфштрем (Атлантик океандагы җылы агым).

**ГОМЕРИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*: **гомерический смех** — тыела алмый шаркылдап көлү.

**ГОМОЗИ'ТЬСЯ** *несов. обл.* — маташу, кайнашу, мәш килү, мыж килү.

**ГО'МОН** *м. мн.* нет, *разг.* — шау-шу, чыр-чу; тавыш; *птичий гомон* — кошлар тавышы, кошлар чырылдавы.

**ГОМОНИ'ТЬ** *несов. обл.* — кычкырып сөйләшү, шау-шу килү, чыр-чу килү, тавышлану.

**ГОМОСЕКСУАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — гомосексуализм (үз җенесенә карата җенси азгынлык).

**ГОМОСЕКСУАЛИ'СТ** *м. книж.* — гомосексуалист (гомосексуализм белән авыручы).

**ГОН** *м. обл.* — 1. *(гнать)* куу; 2. *(место охоты)* ау урыны (кайбер җанварларга карата); 3. ара (электә ике станция арасы).

**ГОНГ** *м. муз.* — гонг (чаң кагып уйнала торган музыка коралы; сигнал бирү өчен дә кулланыла).

**ГОНДО'ЛА** *ж.* — гондола (1. Венециядә каюталы махсус көймә; 2. *ав.* һава шарында кеше утыра торган зур кәрзин; дирижабльдә кеше утыра торган яки механизм куела торган, асылмалы урын).

**ГОНЕ'НИЕ** *ср. книж.* — эзәрләү, эзәрлекләү, кысу, җәберләү.

**ГОНЕ'Ц** *м. устар.* — 1. атчабар, хәбәр йөртүче (элек); 2. *перен.* хәбәрче.

**ГОНИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — *(преследователь)* эзәрлекләүче; *(притеснитель)* кысучы, изүче, җәберләүче.

**ГО'НКА** *ж.* — 1. *(действие)* к. гнать и гнаться 1; 2. *разг.* *(спешка)* ашыгу, кабалану; 3. *разг.* *(перегонка)* куу (мәсәлән, дегет); 4. *обл.* *(сплав леса)* сал агызу. ◇ **Задать гонку** *разг. фам.* — арт сабагын укыту (тиргәү, битәрләү, бик каты орышу). **Гонка вооружений** — ашыгып кораллану, коралланыны арттыру.

**ГО'НКИ** *мн. спорт.* — узышу, ярыш, чабыш (мәсәлән, велосипедта, көймәдә); *автомобильные гонки* — автомобильдә узышу, ярышу.

**ГО'НКИЙ** — 1. *охот.* йөгерек, җитез, нык чаба торган; *гонкая борзая* — нык чаба торган бурзай; 2. *простореч.* *(лёгкий на ходу)* җиңел, тиз йөрешле (көймә); 3. *обл. спец.* *(о деревьях)* төз, биек.

**ГО'НОР** *м. м.* нет, *разг.* — һавалылык, артык горурлык, тәкәбберлек.

**ГОНОРА'Р** *м.* — гонорар (художникларга, язучыларга һ. б. договор буенча түләнә торган хак).

**ГОНОРА'РНЫЙ** — гонорар ...-ы; *гонорарный фонд* — гонорар фонды.

**ГОНОРЕ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — гонорея (венерик авыру).

**ГО'НОЧНЫЙ** — узышу ...-ы (узышу өчен кулланыла торган); *гоночная лодка* — узышу көймәсе.

**ГОНЧА'Р** *м.* — чүлмәкче (чүлмәк ясаучы).

**ГОНЧА'РНЫЙ** — чүлмәк ясау ...-ы, чүлмәк ...; *гончарное производство* — чүлмәк ясау производствосы; *гончарные товары* — чүлмәк товарлар.

**ГО'НЧАЯ** *ж.* — ау эте.

**ГО'НЩИК** *м.* — 1. *спорт.* ярышчы, узышчы; узышу ярышында катнашучы; 2. *обл.* куучы (мәсәлән, дегет куучы).

**ГОНЯ'ТЬ** *несов.* — 1. куу, куып йөртү; 2. *разг.* *(много раз посылать)* йөртеп тору, анда-монда йөгертү, йомыш белән йөртү; 3. *простореч.* чаптыру, йөреп тору, бару; *он каждый день в город гоняет* — ул көн саен шәһәргә чаптыра (йөреп тора). ◇ **Гонять лодыря** или **собак** *разг. фам.* — эт куып йөрү, җил куып йөрү, эшсез йөрү, тик йөрү. **Гонять голубей** — күгәрчен очыру.

**ГОНЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — куып йөрү, арттан йөрү.

**ГОП** *межд.* — һоп! һуп!

**ГОПА'К** *м. мн.* нет — гопак (Украина халык биюе).

**ГО'ПАТЬ** *несов. обл.* — сикерү.

**ГО'ПЛЯ** *межд.* — к. гоп.

**ГО'ПНУТЬ** *сов. однокр. обл.* — сикереп кую.

**ГОРА'** I *ж.* — 1. тау; 2. *перен. разг.* бик күп, өем-өем, тау-тау; *во дворе лежат горы ящиков* — ишек алдында тау-тау ящиклар өеме ята; 3. *только мн.* таулар, таулы урын; *жить в горах* — таулы урында яшәү.

◇ **Идти в гору** *перен.* — югары күтәрелү, уңышларга ирешү. **Идти под гору** — түбән төшү, кире китү. **Гора с плеч** *разг.* — җиңеләеп калу, җилкәдән тау төшкән кебек булу. **Не за горами** *разг.* — тиздән, күп калмады инде, ерак түгел. **Стоять горой** — бөтен көч белән яклау (берәүне); тау кебек тору. **Сулить золотые горы** — күпне ышандыру, алтын таулар вәгъдә итү. **Пир горой** *разг.* — мул сый. **Надеяться как на каменную гору** *разг.* — нык ышану.

**ГОРА' II: на-гора** — җир өстенә, өскә (шахтёрлар телендә); *шахтёры выдали на-гора миллионы тонн угля* — шахтёрлар җир өстенә миллионнарча тонна күмер чыгардылар.

**ГОРА'ЗД** *разг.* — оста, булдыра; *он на всё горазд* — ул бөтен нәрсәне булдыра (аның кулыннан бөтен нәрсә килә).

**ГОРА'ЗДО** *нареч.* — күп, шактый, байтак; *в Казахстане гораздо теплее, чем в Москве* — Казахстанда Москвага караганда шактый җылырак.

**ГОРБ** *м.* — **1.** *(у человека)* бөкре; **2.** *(у верблюда)* өркәч. ◇ **Своим горбом (добывать, зарабатывать)** *разг.* — үз җилкәсе белән, үз кул көче белән (табу, казану). **Наложить по горбу** *простореч.* — җилкәсенә кундыру (кыйнау). **Чужим горбом жить** — кеше җилкәсен кимерү, кеше җилкәсендә яшәү.

**ГОРБА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — бөкрелек.

**ГОРБА'ТЫЙ** — **1.** бөкре; *(сутулый)* бөкрәйгән; **2.** калку; *горбатый мост* — калку күпер; **3.** кәкрәеп килгән, кәкре; *горбатый нос* — кәкре (кәкрәеп килгән) борын.

**ГОРБА'Ч** *м.* — **1.** *(о человеке)* к. горбун; **2.** *столярн.* бөкре ышкы.

**ГО'РБИК** *м.* — **1.** кечкенә бөкре; **2.** *(у верблюда)* кечкенә өркәч.

**ГО'РБИТЬ** *несов. разг.* — бөкрәйтү.

**ГО'РБИТЬСЯ** *несов.* — бөкрәю.

**ГОРБУ'Н** *м.*, **ГОРБУ'НЬЯ** *ж.* — бөкре кеше.

**ГОРБУ'ША** *ж.* — **1.** *зоол.* горбуша (Ерак Көнчыгыш диңгезләрендә яшәүче балык); **2.** *обл. с-х.* бөкре чалгы; **3.** к. горбыль.

**ГОРБУ'ШКА** *ж. разг.* — кибән башы, кыерчык.

**ГОРБЫ'ЛЬ** *м. тех.* — горбыль, кыртыш (бүрәнәне ярганда ике кырыйда кала торган такта).

**ГОРДЕЛИ'ВО** *нареч.* — горурланып, тәкәбберләнеп, масаеп.

**ГОРДЕЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — горурлык, тәкәбберлек, масаючанлык, һавалылык.

**ГОРДЕЛИ'ВЫЙ** — горур, тәкәббер, һавалы.

**ГОРДЕ'Ц** *м.* — тәкәббер, горур, мактанчык.

**ГО'РДИЕВ У'ЗЕЛ** *м.* — Гордий төене (*перен.* бик чуалчык мәсьәлә, чишүе кыен булган мәсьәлә).

**ГОРДИ'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** горурлану; *мы гордимся своей советской Родиной* — без үзебезнең совет Ватаны белән горурланабыз; **2.** *(кичиться)* тәкәбберләнү, эреләнү, борын күтәрү, масаю, эре тоту.

**ГО'РДО** *нареч.* — **1.** горур рәвештә, горурланып; **2.** *(высокомерно)* тәкәбберләнеп, эреләнеп; **3.** *(величаво)* мәһабәт рәвештә.

**ГОРДОВИ'НА** *ж. бот.* — кара балан (куак үсемлек).

**ГО'РДОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** горурлык; мактаныч; *чувство национальной гордости* — милли горурлык тойгысы; *этот дом — гордость нашего города* — бу йорт безнең шәһәрнең мактанычы; **2.** *(высокомерие)* тәкәбберлек, һавалылык; **3.** *(величавость)* мәһабәтлек.

**ГО'РДЫЙ** — **1.** *(исполненный гордости)* горур; *гордый человек* — горур кеше; **2.** *(надменный)* тәкәббер, һавалы, эре; **3.** *(величавый)* мәһабәт.

**ГОРДЫ'НЯ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.* — үтә тәкәбберлек, артык һавалылык.

**ГОРДЯ'ЧКА** *ж. разг. фам. неодобр.* — тәкәббер, масаючан (хатын-кыз).

**ГО'РЕ** *ср. мн.* нет — **1.** *(скорбь, печаль)* кайгы, хәсрәт, көенеч, сагыш; **2.** *(несчастье)* бәхетсезлек, бәла-каза; *горе в том, что...* — бәла шунда.... ◇ **А ему и горя мало** *разг.* — аның исендә дә юк, ике ятып бер төшенә дә керми, аның бер дә исе китми. **К моему горю, на моё горе** *разг.* — бәхетсезлегемә каршы. **Помочь горю** — ярдәм итү, кайгысын уртаклашу.

**[ГОРЕ-]** *(нач. часть сложных слов)* — начар, яраксыз, булдыксыз; *горе-охотник* — булдыксыз аучы.

**ГОРЕВА'ТЬ** *несов.* **1.** *(испытывать скорбь)* кайгыру, хәсрәтләнү, көенү, сагышлану, хәсрәт чигү; **2.** *простореч.* *(бедствовать)* мохтаҗлыкта яшәү, фәкыйрьлектә яшәү.

**ГОРЕ'ЛКА I** *ж.* — **1.** *тех.* *(у примуса)* горелка; **2.** *(у лампы)* челтәр.

**ГОРЕ'ЛКА II, ГОРИ'ЛКА** *ж. мн.* нет, *обл.* — аракы.

**ГОРЕ'ЛКИ** *только мн.* — так-җеп уены, там-тамук уены, так-каравыл уены.

**ГОРЕ'ЛЫЙ** — **1.** янган, көйгән; *горелая доска* — янган такта; **2.** черегән; *горелая кожа* — черегән күн; **3.** кызган; *горелое зерно* — кызган ашлык. **4.** *в знач. сущ.* көек; *пахнет горелым* — көек исе килә.

**ГОРЕМЫ'КА** *м.* и *ж. разг. нар.-поэт.* — бичара, бәхетсез, мескен (кеше), хәсрәт капчыгы.

**ГОРЕМЫ'ЧНЫЙ** *разг. фольк.* — кайгы-хәсрәтле, көенечле, бәхетсез, кара, караңгы; *горемычная доля* — бәхетсез язмыш, кара язмыш.

**ГО'РЕНКА** *ж. устар. обл.* — к. горница.

**ГРУДИ'НА** *ж.* — 1. *анат.* күкрәк сөяге, түш сөяге; 2. *книж.* к. грудинка.

**ГРУДИ'НКА** *ж.* — 1. *(часть туши)* түш ите; 2. грудинка (түш итеннән пешерелгән жаркой).

**ГРУДНИ'ЦА** *ж. мед.* — имчәк шешү.

**ГРУДНО'Й** — 1. күкрәк ...-ы; *грудная клетка* — күкрәк читлеге; 2. имчәк ...-ы; *грудной ребёнок* — имчәк баласы. ◇ **Грудная жаба** — күкрәк бакасы (йөрәк авыруы). **Грудные болезни** *разг. устар.* — үпкә авырулары. **Грудной голос** — күкрәктән чыккан тавыш.

**ГРУДОБРЮ'ШНЫЙ**: **грудобрюшная преграда** *анат.* — күкрәк-корсак пәрдәсе, түш ярысы, диафрагма.

**ГРУДЬ** *ж.* — 1. *анат.* күкрәк, түш; *пуля прострелила грудь навылет* — пуля күкрәгеи тишеп чыккан; 2. *(женская)* имчәк; 3. *разг.* күкрәкчә; *вышитая грудь* — чигелгән күкрәкчә. ◇ **В грудях болит** *обл. простореч.* — күкрәгем авырта. **Стоя'ть грудью** — күкрәк киереп каршы тору, яклау. **Кормить грудью** — имезү.

**ГРУЖЁНЫЙ** — йөкле (буш түгел), йөк төялгән.

**ГРУЗ** *м.* — 1. *(тяжесть)* авырлык, авыр нәрсә; 2. *(товар)* груз, йөк; 3. *перен. (бремя)* йөк, авырлык.

**ГРУЗДЬ** *м. бот.* — гөрәҗдә, нарат гөмбәсе, кәҗә гөмбәсе.

**ГРУЗИ'ЛО** *ср.* — батыргыч (кармак җебенә яки балык ятьмәсенә бәйләп куелган авыр нәрсә).

**ГРУЗИ'НСКИЙ** — грузин ...-ы, Грузия ...-ы; *грузинский чай* — грузин чәе; *грузинская земля* — Грузия җире.

**ГРУЗИ'НЫ** *мн.* (*ед.* грузин) — грузиннар, грузин халкы.

**ГРУЗИ'ТЬ** *несов.* — төяү; *грузить дрова на баржу* — баржага утын төяү.

**ГРУЗИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. төяну (юлга чыгар алдыннан); 2. *страд.* төялү.

**ГРУЗНЕ'ТЬ** *несов. разг.* — авыраю.

**ГРУ'ЗНО** *нареч.* — салмак рәвештә, талгын гына, салмак кына.

**ГРУ'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — салмаклык, авырлык; авыр гәүдәле булу, авыр сөякле булу.

**ГРУ'ЗНЫЙ** — авыр һәм зур; авыр сөякле, авыр гәүдәле.

**ГРУЗОВИ'К** *м.* — грузовик, йөк автомобиле.

**ГРУЗОВЛАДЕ'ЛЕЦ** *м. торг.* — груз хуҗасы, йөк хуҗасы.

**ГРУЗОВМЕСТИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — йөк сыйдырыш.

**ГРУЗОВО'Й** — йөк ...-ы; *грузовой автомобиль* — йөк автомобиле.

**ГРУЗООБОРО'Т** *м. экон.* — груз әйләнеше (билгеле вакыт эчендә бер юлда ташылган йөк хисабы).

**ГРУЗООТПРАВИ'ТЕЛЬ** *м. торг.* — груз җибәрүче.

**ГРУЗОПЕРЕВО'ЗКА** *ж.* — груз ташу, йөк ташу, йөк йөртү.

**ГРУЗОПОДЪЁМНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *тех.* — йөк күтәрүчәнлек, авырлык күтәрә алу дәрәҗәсе.

**ГРУЗОПОДЪЁМНЫЙ** *тех.* — йөк күтәрү ...-ы; йөк (авырлык) күтәрә торган; *грузоподъёмный кран* — йөк күтәрү краны.

**ГРУЗОПОЛУЧА'ТЕЛЬ** *м. торг.* — груз алучы (исеменә йөк җибәрелгән кеше яки учреждение).

**ГРУ'ЗЧИК** *м.* — грузчик (йөк төяүче, йөк бушатучы).

**ГРУНТ** *м.* — 1. *(почва)* туфрак, җир, балчык, грунт; *песчаный грунт* — комлы туфрак; 2. *маляр. живоп.* җирлек, грунт (агачка яки киндергә беренче кат сөртелгән буяу); 3. штрихланган фон (рәсемдә).

**ГРУНТОВА'ТЬ** *несов. маляр. живоп.* — грунтлау (рәсем ясаласы яки буяласы әйберне беренче кат буяп чыгу).

**ГРУНТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд., маляр. живоп.* — грунтлану.

**ГРУНТОВО'Й** — грунт ...-ы; җирдә кышлый торган; *грунтовые воды* — грунт сулары (җир астыннан чыга торган сулар);

*грунтовые растения* — жирдә (туфракта) кышлый торган үсемлекләр.

**ГРУ'ППА** *ж.* — группа, төркем.

**ГРУППИРОВА'ТЬ** *несов. книж.* — группалау, төркемләү, төркемнәргә җыю; төркемнәргә бүлү, төркемнәргә аеру.

**ГРУППИРОВА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. группаларга оешу, группаларга җыелу, группаларга туплану; 2. *страд.* төркемнәргә бүленү.

**ГРУППОВО'Д** *м.* — группа житәкчесе.

**ГРУППОВО'Й** — группа ... -ы, группа белән ... ; группалап ... ; *групповое собрание* — группа җыелышы; *групповой снимок* — группа белән төшкән рәсем; *групповая сдельщина* — группалап эш башыннан эшләү.

**ГРУППОВЩИ'НА** *ж. мн.* нет, *неодобр.* — группачылык.

**ГРУСТИ'ТЬ** *несов.* — ямансылау, сагыну, юксыну, күңелсезләнү.

**ГРУ'СТНО** *нареч.* — күңелсез, күңелсезләнеп, ямансылап.

**ГРУ'СТНЫЙ** — күңелсез, кайгылы, ямансу, моңсу, авыр; *грустное известие* — күңелсез хәбәр, кайгылы хәбәр; *грустная песня* — моңсу җыр; *грустная картина нищеты в колониальных странах* — колониаль илләрдә хәерчелекнең авыр күренеше; *грустный результат* — күңелсез нәтиҗә.

**ГРУСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *книж. поэт.* кайгы, сагыш, хәсрәт; 2. *перен. разг. фам.* хәсрәт, бәла; *работать с этим лентяем — одна грусть* — бу ялкау белән эшләү хәсрәт кенә.

**ГРУ'ША** *ж.* — 1. *(плод)* груша; 2. *(дерево)* груша агачы.

**ГРУША'НКА** *ж. бот.* — каеш яфрак (үлән).

**ГРУШЕВИ'ДНЫЙ** *книж.* — грушасыман.

**ГРУ'ШЕВЫЙ** — грушадан ясалган; груша ...-ы; *грушевое дерево* — груша агачы; *грушевый сироп* — груша сиробы (грушадан ясалган сироп).

**ГРУШО'ВКА** *ж. мн.* нет — 1. *(наливка)* груша эчемлеге; 2. *(сорт яблок)* грушовка.

**ГРЫ'ЖА** *ж. мед.* — бөсер.

**ГРЫ'ЗЛО** *ср. спец.* — авызлык.

**ГРЫЗНЯ'** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. *(между животными)* тешләшү, талашу; 2. *перен. фам. неодобр.* әрләшү, кычкырышу, ачуланышу, сүгешү, ызгышу.

**ГРЫЗОВО'Й** — ашый торган; *грызовой сорт подсолнухов* — көнбагышның ашый торган эре сорты.

**ГРЫЗТЬ** *несов.* — 1. кимерү; *грызть кость* — сөяк кимерү; 2. ашау; *грызть орехи* — чикләвек ашау; 3. *перен. разг. фам неодобр.* чәйнәү, талау, колак итен ашау (тиргәп тору мәгънәсендә); *ты грызёшь меня с утра до вечера* — син мине иртәдән кичкә чаклы талыйсың (тиргәп торасың); 4. *перен.* борчу, җәфалау; *его грызут сомнения* — аны шикләнүләр борчый.

**ГРЫ'ЗТЬСЯ** *несов.* — 1. *(о животных)* тешләшү, талашу; *собаки грызутся* — этләр талаша; 2. *перен. разг. фам.* тиргәшү, талашу, әрләшү, кычкырышу; *империалисты грызутся из-за колоний* — империалистлар колонияләр өчен талашалар.

**ГРЫЗУ'Н** *м. зоол.* — кимерүче (күсе, тычкан, йомран һ. б. турында).

**ГРЫ'МЗА** *м. простореч. бран.* — мыгырдык.

**ГРЯДА'** *ж.* — 1. *(на огороде)* түтәл; 2. *геол.* таулар тезмәсе; *Урало-Карпатская гряда* — Урал-Карпат таулары тезмәсе. 3. *книж. (цепь подводных камней)* ташлар тезмәсе. ◇ **Редеет облаков летучая гряда** *книж. поэт.* — агылып бара торган болытлар сирәгәя.

**ГРЯДИ'ЛЬ** *м. с.-х.* — грядиль, сабан кысасы.

**ГРЯ'ДКА** *ж.* — 1. түтәл; 2. *спец. (перекладина)* арата; 3. үрәчә.

**ГРЯ'ДКОВЫЙ** *с.-х.* — түтәл ...-ы; *грядковая культура* — түтәл культурасы.

**ГРЯДНО'Й** — түтәл ...-ы; түтәлдә үсә торган; *грядные огурцы* — түтәл кыяры, түтәлдә үсә торган кыяр.

**ГРЯДУ'ЩЕЕ** *в знач. сущ. ср. мн.* нет — киләчәк; *в грядущем нас ждут новые победы* — киләчәктә безне яңа җиңүләр көтә.

**ГРЯДУ'ЩИЙ** *книж. ритор.* — киләчәк, якынлашып килә торган; *грядущие события* — якынлашып килә торган вакыйгалар. ◇ **На сон грядущий** *разг.* — йокы алдыннан.

**ГРЯЗЕВО'Й** — 1. *геол.* лай ...-ы, лай чыгара торган; *грязевой вулкан* — лай вулканы; 2. *мед.* лай ...-ы; лай белән ... ; *грязевая ванна* — лай ваннасы; *грязевое лечение* — лай белән дәвалау.

**ГРЯЗЕЛЕЧЕ'БНИЦА** *ж. мед.* — грязелечебница, лай белән дәвалау учреждениесе.

**ГРЯЗЕЛЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.* — лай белән дәвалау; лай белән дәвалану.

**ГРЯЗИ'ЩА** *ж. мн.* нет, *разг.* — пычрак, пычраклык.

**ГРЯЗНЕ'ТЬ** *несов. разг.* — пычрану, буялу, керләнү, каралу.

**ГРЯЗНИ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. пычрату, буяу, керләндерү, тап төшерү, каралту; 2. *(мусорить)* чүпләү.

**ГРЯЗНИ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. пычрану, буялу, керләнү, таплану, каралу; 2. *(мусориться)* чүпләнү.

**ГРЯ'ЗНО** *нареч.* — пычрак, әшәке; *грязно пишет* — пычрак яза.

**ГРЯЗНУ'ЛЯ** *м.* и *ж.* — к. грязнуха.

**ГРЯ'ЗНУТЬ** *несов.* — бату, пычракка бату; батып калу.

**ГРЯЗНУ'ХА** *м.* и *ж. разг.* — пычрак, шапшак, шакшы (кеше).

**ГРЯЗНУ'ШКА** *м.* и *ж.* — к. грязнуха.

**ГРЯ'ЗНЫЙ** — 1. пычрак, быкырдык, әшәке; *грязная дорога* — пычрак юл; 2. *(запачканный)* буялган, пычранган; *(о белье)* керләнгән, каралган; 3. *(о цвете)* соргылт-тонык; 4. шакшы; *грязное ведро* — шакшы чиләге; шакшы чиләк; 5. *перен.* әшәке, бозык, нәҗес (кеше).

**ГРЯЗЬ** *ж.*— 1. *только ед.* пычрак, баткак, быкырдык; 2. *только ед. (нечистота — (о теле, о белье)* кер; 3. *только ед. перен. (грязные поступки)* пычраклык, әшәкелек; 4. *обл. (топкие места)* баткаклык; 5. *только мн. мед.* лай; *принимать грязи* — лай белән дәвалану; 6. *(сор, отбросы)* чүп-чар. ◇ **Не ударить лицом в грязь** *разг.*— йөзгә кызыллык китермәү (йөкләнгән эшне намус белән эшләү). **Месить грязь** *разг.*— пычрактан бару, пычрак ерып бару. **Забросать грязью** или **смешать с грязью** — өскә пычрак ташлау (яла ягу, нахакка гаепләү).

**ГРЯ'НУТЬ** *сов. однокр.*— 1. гөрселдәү, гөрселдәп китү; күкрәү, күкрәп китү, яңгырау, яңгырап китү; *гром грянул* — күк күкрәде; *далече грянуло ура* — еракта ура кычкырган тавышлар яңгырады; 2. *перен.* башлану, башланып китү; *грянула война* — сугыш башланып китте; *грянула буря* — давыл башланып китте.

**ГРЯ'НУТЬСЯ** *однокр.*— дөберт итеп аву, шап итеп егылу.

**ГРЯСТИ'** *несов., книжн. ритор.*— якынаю, якынлашып килү; *„грядет пролетарская революция"* (Ленин) — пролетариат революциясе якынлашып килә.

**ГУА'ШЬ** *ж. мн.* нет, *живоп.*—гуашь (1. үтә күренми торган акварель буяу; 2. шундый буяу белән ясалган рәсем).

**ГУБА'** I *ж.*— 1. ирен; 2. *только мн.* борын (келәшчәдә, кыскычта). ◇ **По губам помазать** *разг.*— ымсыту, ымсындыру; вәгъдә итеп тә бирми калдыру. **Молоко на губах не обсохло** *разг.*— авызыннан сөте кипмәгән, борын асты кипмәгән (яшь, тәҗрибәсез). **У него губа не дура** — үз файдасын белә. **Надуть губы** — ирен турсайту, үпкәләү. **Заячья губа** *мед.*— китек ирен. **Распустить губы** — селәгәен агызу.

**ГУБА'** II *ж. бот.*— агач гөмбәсе.

**ГУБА'** III *ж. геогр.*— култык; *Обская губа* — Обь култыгы.

**ГУБА'** IV *ж. истор.*— губа (XVI—XVII йөзләрдә рус дәүләтендә административ-территориаль округ).

**ГУБА'** V *ж. истор.*— губа (Москва Русенда губа старостасына буйсынган суд округы).

**ГУБА'СТЫЙ** *разг. фам.*— зур иренле, калын иренле.

**ГУБЕРНА'ТОР** *м.*— губернатор (1. *истор.* элекке Россиядә губерна башлыгы; 2. колония башлыгы; АКШ та штат башлыгы).

**ГУБЕРНА'ТОРСКИЙ** *дореволь.*— губернатор ...-ы; **губернаторский дом** — губернатор өе. ◇ **Положение хуже губернаторского** *разг. шутл.*— эшләр шәптән түгел, эшләр хөрти, хәл бик начар.

**ГУБЕРНА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *дореволь.*— губернаторлык; губернаторлык вазифасы.

**ГУБЕРНА'ТОРША** *ж. дореволь.* — губернатор хатыны.

**ГУБЕ'РНИЯ** *ж. истор.*— 1. губерна (элек Россиядә административ-территориаль бәрәмлек); 2. *простореч. устар.* губерна шәһәре. ◇ **Пошла писать губерния** *перен. разг. шутл.*— ыгы-зыгы башланды, ду купты.

**ГУБЕ'РНСКИЙ** *истор.* — губернадагы, губерна ...-ы; *губернский город* — губерна шәһәре.

**ГУБИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ГУБИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книжн.*— һәлак итүче, харап итүче.

**ГУБИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книжн.*— һәлакәтлелек.

**ГУБИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книжн.* — 1. һәлакәтле, һәлакәткә китерә торган, һәлак иткеч, харап иткеч, юк иткеч, җимергеч; *губительный огонь артиллерии* — артиллериянең һәлак иткеч уты, җимергеч уты; 2. сәламәтлеккә зарарлы, сәламәтлеккә зарар китерә торган; *губительный климат* — сәламәтлеккә зарарлы климат.

**ГУБИ'ТЬ** *несов.*— һәлак итү, харап итү; бозу, бетерү.

**ГУ'БКА** I *ж.*— ирен.

**ГУ'БКА** II *ж.* — губка, болыт (1. *зоол.* суда яши торган тереклек иясе; 2. губканың гәүдәсеннән яки шуна охшатып резинадан ясалган һәм мунчада мунчала урынына кулланыла торган әйбер).

**ГУ'БКА** III *ж. бот. разг.*— кечкенә гөмбә, гөмбәчек (агачларда).

**ГУБНО'Й** — ирен ...-ы; *губные звуки* — ирен авазлары; *губная помада* — ирен помадасы.

**ГУБОШЛЁП** *м. простореч.* — 1. салпы ирен, алаша ирен, бәлеш авыз; 2. *бран.* булдыксыз, мәми авыз.

**ГУ'БЧАТЫЙ** — вак-вак тишекле, күз-күз тишекле, көпшәк, болытсыман.

**ГУВЕРНА'НТКА** *ж. устар.*— гувернантка (буржуаз семьяда балаларга өйдә тәрбия һәм башлангыч белем бирүче хатынкыз, гадәттә чит ил хатын-кызы).

**ГУВЕРНЁР** *м. устар.* — гувернёр (буржуаз семьяда балаларга өйдә тәрбия һәм башлангыч белем бирүче ир кеше, гадәттә чит ил кешесе).

**ГУГЕНО'ТЫ** *мн.* (*ед.* гугенот) *истор.* — гугенотлар (XVI—XVII йөзләрдә француз протестантлары).

**ГУГНИ'ВЫЙ** — тынкыш, борын аша сөйләшүче.

**ГУ-ГУ'**: **ни гу-гу** *разг.*— 1. *(приказание, просьба молчать)* дәшмә, тынычны да чыгарма, авызыңны да ачасы булма, ләммим әйтмә, май кап; 2. *(не подаёт голоса)* дәшми, тынын да чыгармый, авызын да ачмый.

**ГУДЕ'ТЬ** *несов.* — гүләү, гөрелдәү, гүелдәү; *(о насекомых)* уылдау, жуылдау, шаулау; шаулап тору; жу-у-у итеп тору; *от шума машины у меня гудит в ушах* — машина тавышыннан колакларым шаулап тора; *(о сирене, паровозе, гудке)* кычкыру, кычкырту; *гудок гудит* — гудок кычкырта.

**ГУДО'К** I *м.*— гудок (борынгы русларда скрипкасыман өч кыллы музыка коралы).

**ГУДО'К** II *м.*— 1. гудок (автомобильдә, паровозда, завод-фабрикаларда һ. б.); 2. гудок, кычкырту; *гудок парохода* — пароход гудогы, пароход кычкыртуы.

**ГУДРО'Н** *м. мн.* нет, *тех.*— гудрон (ташкүмер сумаласыннан яки нефть калдыкларыннан кайнатып чыгарыла торган кара масса).

**ГУДРОНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*, *тех.*— гудронлау, гудрон җәю.

**ГУДРОНИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*, *тех.*— гудронлану, гудрон җәелү.

**ГУЖ** *м.*— 1. камыт бавы; 2. *устар.* җигүле транспорт; *не хватило гужа для перевозки хлеба* — икмәк ташу өчен җигүле транспорт җитмәде.

**ГУЖЕВО'Й** — 1. камыт бавы ...-ы; *гужевая петля* — камыт бавы элмәге; 2. җигүле; *гужевой транспорт* — җигүле транспорт.

**ГУЖО'ВКА** *ж.*— камыт баулык (камыт бавы өчен китә торган каеш).

**ГУЛ** *м. мн.* нет — 1. *(отдалённый шум большой силы)* гөрселдәү тавышы, дөберләү тавышы, гөрелдәү тавышы; 2. гөр килеп тору; *я ничего не мог разобрать в гуле голосов* — гөр килеп торган тавыш эчендә мин бернәрсә дә аңлый алмадым.

**ГУЛЁНА** *м.* и *ж. простореч. неодобр.*— биләмче.

**ГУ'ЛЕНКА** *ж. разг. дет.* — күгәрченкәем.

**ГУ'ЛКИЙ** — 1. яңгыравыклы, яңгыраулы; *гулкие своды* — яңгыраулы гөмбәзләр; 2. яңгыраган; *гулкий звук* — яңгыраган тавыш.

**ГУЛЬБА'** *ж. мн.* нет, *простореч.*— типтерү.

**ГУ'ЛЬБИЩЕ** *ср. устар.*— халык гуляньесы урыны.

**ГУЛЬ-ГУЛЬ** *звукоподраж.* — гөр-гөр (күгәрчен чакыру сүзләре).

**ГУ'ЛЬДЕН** *м.* — гульден (Голландиядә акча берәмлеге).

**ГУЛ(Ь)ЛИ'ВЫЙ** *обл.* — типтерүче, типтерергә яратучы.

**ГУЛЬНУ'ТЬ** *однокр. простореч. фам.*— типтереп алу, гулять итеп алу.

**ГУЛЯ'ВНИК** *м. бот.* — чалгычут (чүп үлән).

**ГУ'ЛЯ** *м.* и *ж. разг. дет.*— к. голубь.

**ГУЛЯ'КА** *м. разг.* — 1. биләмче; типтерүче; 2. *бран.* мут, исерекбаш, бозык.

**ГУЛЯ'НКА** *ж. простореч.* — 1. күңел ачу мәҗлесе; 2. буш вакыт, эштән буш вакыт.

**ГУЛЯ'НЬЕ** *ср.*— 1. *(действие)* к. гулять 1, 3; 2. гулянье; *сегодня в саду состоится большое гулянье* — бүген бакчада зур гулянье булачак.

**ГУЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. *(совершать прогулку)* йөрү, ачык һавада йөрү, күңел ачып йөрү; 2. *разг.* *(быть свободным от работы)* эшсез йөрү; 3. *простореч.* *(кутить)* типтерү, эйттерү; 4. *перен.* тик тору, буш яту; *земля гуляет без обработки* — җир эшкәртелмичә буш ята; 5. *разг.* йокламау; *ребёнок ночью долго гулял и не давал нам спать* — бала төнлә озак йокламады һәм безгә дә йокларга бирмәде; 6. *эвф.* *(о собаке)* тышка чыгу; *Жучка просится гулять* — Жучка тышка чыгарга сорый.

**ГУЛЯ'Ш** *м. кулин.*— гуляш (иттән хәзерләнгән ашамлык).

**ГУЛЯ'ЩАЯ** *ж. простореч.*— фахишә, азгын хатын.

**ГУЛЯ'ЩИЙ** *м. простореч.* — типтерүче; *гулящий человек* — типтерүче кеше. ◇ **Гулящие дни** — бәйрәм көннәр, буш көннәр.

**ГУМАНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— 1. *истор.* гуманизм (Яңарыш чорында кешеләрне һәм аларның фикерен феодализм һәм католицизм богауларыннан азат итүгә юнәлдерелгән хәрәкәт); 2. гуманизм, кешелеклелек.

**ГУМАНИ'СТ** *м. книж.*— 1. *истор.* гуманист; 2. *перен.* гуманист, кеше сөюче, кешелекле.

**ГУМАНИСТИ'ЧЕСКИЙ** — гуманистик, гуманизм...-ы; *в гуманистических целях* — гуманистик максатлардан чыгып.

**ГУМАНИТА'РНЫЙ** *книж.* — гуманитар, иҗтимагый; *гуманитарные науки* — гуманитар фәннәр, иҗтимагый фәннәр (философия, тарих, филология һ. б.).

**ГУМА'ННО** *нареч.* — кешелекле, шәфкатьле, йомшак; *гуманно обращаться* — кешелекле мөгамәләдә булу.

**ГУМА'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — кешелеклелек, шәфкатьлелек, йомшак күңеллелек.

**ГУМА'ННЫЙ** *книж.* — кешелекле, йомшак күңелле, шәфкатьле, кешегә карата игътибарлы; *гуманное отношение* — кешелекле мөнәсәбәт.

**ГУ'МКАТЬ** *несов. разг.* — һе-е дип тору (кеше сөйләгәндә).

**ГУ'ММИ** *ср. нескл.*— гумми, сәмих (кайбер агачлардан агып чыга торган җилемсыман сыекча).

**ГУММИ-АРА'БИК** *м.*— гумми-арабик (кәгазь ябыштыра торган җилемнең бер төре).

**ГУММИ'РОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — җилем сөртү.

**ГУММО'З** *м. мн.* нет, *бот.*— гуммоз, сәмих агу (үсемлекләрдә була торган авыру).

**ГУМНО'** *ср.*— ындыр.

**ГУ'МУС** *м. мн.* нет, *с.-х.*— гумус, черемә (туфракның өске катлавы).

**ГУНДО'СИТЬ** *несов. простореч.* — тынкышлану, борын аша сөйләү.

**ГУ'ННЫ** (*ед.* гунн) — 1. *истор.* гуннар (IV—V йөзләрдә Көнбатыш Европага күчеп килгән борынгы төрки халыклардан бер кабилә); 2. *перен. книж.* вәхшиләр, культура байлыкларын җимерүчеләр.

**ГУ'НЬКА** *ж. мн.* нет, *простореч. обл.*— иске кием, иске-москы, алама-сәләмә.

**ГУНЯ'ВЫЙ** *простореч., обл.* — 1. авырудан пеләшләнгән; 2. йоны коелган, кырылган; *гунявый мех* — йоны коелган мех.

**ГУ'РИЯ** *ж.* — 1. *миф.* хур кызы; 2. *поэт.* гүзәл кыз (Көнчыгыш илләрдә).

**ГУРМА'Н** *м.*, **ГУРМА'НКА** *ж.* — гурман, тәмлетамак, татлытамак (тәмле-татлы ашамлыкларны яратучы).

**ГУРМА'НСТВО** *ср. мн.* нет — 1. гурманлык, тәмле тамаклылык; 2. гурманлык, яхшы әйберләргә һәвәслелек.

**ГУРТ** *м.* — көтү, гурт.

**ГУРТОВЩИ'К** *м.* — 1. *(погонщик)* гурт куучы, көтү куучы; 2. *(продавец гурта)* гурт сатучы.

**ГУРТО'М** *нареч.* — 1. *(оптом)* тулаем, көтүе белән; 2. *разг.* җыйнаулашып, барысы бергә, бөтенесе бергә; *гуртом отправились купаться* — барысы бергә су коенырга киттеләр.

**ГУРЬБА'** *ж. мн.* нет — шау-шулы төркем.

**ГУРЬБО'Й** *нареч.* — өелеп, җыелышып, барысы бергә.

**ГУСА'К** *м.* — ата каз.

**ГУСА'Р** *м. дореvол.* — гусар (элек җиңел кавалериядә хезмәт итүче). ◇ **Запустить в нос гусара** *устар.* — йоклаган кешенең борынына кәгазь бөтереп тыгу.

**ГУСА'РСКИЙ** *дореvол.* — гусар ...-ы; *гусарский полк* — гусар полкы.

**ГУСЕВО'ДСТВО** *ср.* — каз асраучылык.

**ГУСЁК** *м. разг.* — 1. кечкенә каз; 2. каз уены (шакмаклап сызылган каты кәгазь өстендә фигуралар йөртеп уйнала торган уен).

**ГУ'СЕЛЬНЫЙ** — гөслә ...-ы; *гусельный мастер* — гөслә мастеры.

**ГУ'СЕМ** *нареч. устар.* — к. гуськом.

**ГУ'СЕНИЦА** I *ж. зоол.* — күбәләк корты.

**ГУ'СЕНИЦА** II *ж. тех.* — гусеница, тәгәрмәч чылбыры (тракторда, танкта һ. б.).

**ГУ'СЕНИЧНЫЙ** — 1. *зоол.* күбәләк корты ...-ы; *гусеничный помёт* — күбәләк корты тизәге; 2. *тех.* чылбырлы; *гусеничный трактор* — чылбырлы трактор.

**ГУСЁНОК** *м.* (*мн.* гусята) — каз бәбкәсе.

**ГУСЁНЫШ** *м.* — к. гусёнок.

**ГУСИ'НЫЙ** — каз ...-ы; *гусиное яйцо* — каз йомыркасы. ◇ **Гусиная кожа** — каз тиресе, каз тәне, бала йон кабару (туңудан яки куркудан кеше тәненең каз тәне төсле хәлгә керүе). **Гусиные лапки** *перен.* — күз төбендәге җыерчыклар.

**ГУ'СЛИ** *ед.* нет — гөслә (ике кул белән уйнала торган кыллы музыка коралы).

**ГУСЛЯ'Р** *м.* — гөсләче, гөсләдә уйнаучы; гөсләгә җырлаучы.

**ГУСЛЯ'РНЫЙ** — гөслә...-ы; *гуслярный звон* — гөслә тавышы.

**ГУСТЕ'ТЬ** *несов.* — 1. куеру; *клей густеет* — җилем куера; 2. куелану, куелана бару; *лес густеет* — урман куелана.

**ГУСТИ'** *несов. обл. поэт.* — гүләү, гү итү, шаулау.

**ГУСТИ'ТЬ** *несов. простореч.* — куерту, куеландыру.

**ГУСТНЯ'К** *м.* — урман куелыгы, чытырманлык.

**ГУ'СТО** *нареч.* — 1. куе; *густо сеять* — куе чәчү; 2. каты, каты итеп; *густо замесить тесто* — камырны каты итеп изү; 3. *разг. фам. (изобильно)* мул, күп, тулып ята. ◇ **То густо, то пусто** — бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй.

**ГУСТОБРО'ВЫЙ** — куе кашлы.

**ГУСТОВОЛО'СЫЙ** — куе чәчле.

**ГУСТО'Й** — 1. (*о волосах, о жидкости*) куе; 2. (*о растительности*) куе, еш; 3. (*о тесте*) тыгыз, каты; 4. калын; *густой бас* — калын бас (тавыш).

**ГУСТОЛИ'СТВЕННЫЙ, ГУСТОЛИ'СТЫЙ** — куе яфраклы.

**ГУСТОНАСЕЛЁННЫЙ** — күп халыклы, күп кешеле, халык тыгыз утырган; *густонаселённая область* — күп халыклы өлкә, халык тыгыз утырган өлкә.

**ГУСТОНАСАЖДЁННЫЙ** — куе утыртылган, еш утыртылган.

**ГУСТОПСО'ВЫЙ** — 1. муены куе йонлы (эт); 2. *перен.* ата, чыкылдаган, ашып узган, чын үзе; *густопсовый бандит* — ата бандит; *густопсовый взяточник* — чыкылдаган взятка алучы.

**ГУСТОТА'** *ж. мн.* нет — 1. куелык; *густота молока* — сөтнең куелыгы; 2. тыгызлык; *густота населения* — халыкның тыгызлыгы; 3. ешлык; *густота деревьев* — агачларның ешлыгы (куелыгы).

**ГУСТОШЁРСТНЫЙ** — куе йонлы.

**ГУСЫ'НЯ** *ж.* — 1. ана каз; 2. *перен. разг. презр.* булдыксыз хатын.

**ГУСЬ** *м.* — каз. ◇ **Как с гуся вода** — к. вода.

**ГУСЬКО'М** *нареч.* — бер-бер артлы тезелешеп, аллы-артлы. ◇ **Запрячь гуськом** — очлап җигү.

**ГУСЯ'ТИНА** *ж. мн.* нет, *разг.* — каз ите.

**ГУСЯ'ТНИК** *м.* — 1. *(птичник для гусей)* каз кетәге, каз абзары; 2. *(продавец гусей)* каз сатучы; 3. *зоол.* каз карчыгасы.

**ГУТАЛИ'Н** *м.* — гуталин (итек чистарту мае).

**ГУТО'РИТЬ** *несов. обл.* — сөйләү, сөйләшеп утыру, гәпләшү.

**ГУТ(Т)АПЕ'РЧА** *ж. мн.* нет — гуттаперча (каучуксыман матдә).

**ГУТТАПЕ'РЧЕВЫЙ** — гуттаперча...; гуттаперчадан ясалган.

**ГУ'ЩА** *ж. мн.* нет — 1. куелык, куесы; *кофейная гуща* — кофе куесы; 2. куелык, чытырманлык; *гуща леса* — урман куелыгы; 3. *перен.* урта, ара; *машина врезалась в гущу народа* — машина халык арасына барып керде. ◇ **Гадать на кофейной гуще** — күрәзәлек итү.

**ГУ'ЩЕ** — куерак; катырак, ешрак.

**ГЯУ'Р** *м.* — кафер (мөселманнарда мөселман булмаган кешеләрнең гомуми исеме).

# Д

**ДА** I *частица* — 1. (*утвердительная*) әйе, шулай; *ты был там? — да, был* — син анда булдыңмы? — әйе, булдым; *отвечай прямо: да или нет?* — туры җавап бир: шулаймы, түгелме? **2.** (*в значении иронического отказа*) һе; *ты пойдёшь? — Да, как бы не так!* — син барасыңмы? — Һе, барам ди, бармыйнн! **3.** (*вопросительная*) шулаймыни? алаймыни? шулаймы? *Он уже приехал. — Да?* — Ул кайтты инде. — Шулаймыни? **4.** (*при внезапном воспоминании*) әй; *да, я ведь должен идти* — әй, мин бит барырга тиеш; **5.** (*при отклике*) нәрсә? ә? *гражданин Иванов! — Да?* — Гражданин Иванов! — Ә ? Нәрсә? **6.** (*так, действительно*) әйе, дөрестән дә; *да, были люди в наше время* — әйе (дөрестән дә), бар иде кешеләр безнең заманда; *там было хорошо, да, очень хорошо* — анда яхшы иде, дөрестән дә, бик яхшы иде. ◇ **Да-да** или **да-да-да** *разг.* — әйе-әйе, шулай-шулай. **Ах, да!** *разг.* — әй!

**ДА** II — 1. (*частица в значении пусть*) ...-сын; *да здравствует Советская Армия!* — Яшәсен Совет Армиясе! *Да продлятся его годы!* — аның гомере озын булсын! **2.** *устар.* (*в значении союза „чтобы" в сочетании с инф.*) ...-у өчен; *Стефан уже сзывал толпы густые, да уничтожить псковитян* (Языков) — псковлыларны тар-мар итү өчен, Стефан бик күп халык җыя иде инде.

**ДА** III *усилительная частица* — 1. (*удивление с сомнением*) ла; *да не может быть?* — булмас ла? **2.** (*настойчивая просьба*) ...-чы, ...-сана; *да помогите же!* — ярдәм итегезче, ярдәм итегезсәнә! **3.** (*в знач. ведь*) бит, ич; *где это написано? — Да в пятой главе* — ул кайда язылган? — Бишенче бүлектә ич; *куда же идти? — Да направо* — кая барырга соң? — Уң якка ич (бит). ◇ **Он когда-нибудь да вернётся** — бер кайтмаса бер кайтыр әле, ул кайчан да булса бер кайтыр. **Что-нибудь да осталось же** — берәр нәрсә калгандыр бит. **Да ну его!** — ташла син аны! **Да и** — да; *думал, думал, да и решил ехать* — уйладым-уйладым да, барырга булдым. **Да и говорить-то об этом не стоит** — бу турыда сөйләп тә торасы юк. **Смеётся, да и только** — көлә дә көлә, бар белгәне көлү. **Спит, да и только** — йоклый да йоклый, бар белгәне йоклау.

**ДА** IV *союз* — 1. (*соединительный*) да, һәм, белән; *он да я* — ул да мин; *моя жена да ребёнок* — хатыным белән балам; 2. (*присоединительный*) өстәвенә, тагын, шуның өстенә, җитмәсә тагын; *шёл я ночью один, да ещё лесом* — төнлә мин берүзем бара идем, җитмәсә тагын урман эченнән; 3. (*противительный*) ләкин, әмма, да; *хочется купить, да карман не позволяет* — аласы килә, ләкин кесә сай.

**ДА'БЫ** *союз устар.* — өчен.

**ДАВА'ТЬ** *несов.* — 1. к. дать; **2.** *пов. накл.* **давай, давайте** — әйдә, әйдәгез, ягез, я әле; *давайте пообедаем* — ягез, аш ашап алыйк; **3.** *разг., пов. накл.* **давай** — башлады, тотынды; *он давай бежать* — ул йөгерергә тотынды.

**ДАВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. даться. ◇ **Диву даваться** — гаҗәпсенү, соклану, шаккату, таңга калу, хәйран калу, исе-акылы китү.

**ДА'ВЕЧА** *нареч. простореч.* — бая, баягынак, күптән түгел.

**ДА'ВЕШНИЙ** *простореч.* — баягы, әлеге.

**ДАВИ'ЛО** *ср. тех.* — изгеч, йөзем изгеч (виноград суын кысып чыгара торган җайланма).

**ДАВИ'ЛЬНЫЙ** *тех.* — кысып чыгара торган, изә торган, сыга торган, сыта торган (тукмак һ. б. әйбер).

**ДАВИ'ЛЬНЯ** *ж. тех.* — давильня (виноград сыгу заведениесе).

**ДАВИ'ЛЬЩИК** *м.* — сыгучы, виноград сыгучы (эшче).

**ДАВИ'ТЬ** *несов.* — 1. басу; *снег давит на крышу* — кар түбәне баса; **2.** кысу; *воротник давит шею* — яка муенны кыса; **3.** таптау, имгәтү, таптап үтерү; *толпа бежала и давила сбитых с ног* — халык төркеме йөгерә һәм егылганнарны таптый иде; 4. сыту, сытып үтерү; *давить клопов* — кандалаларны сыту; **5.** изү, сыгу; *давить ягоды* — җиләк изү; *давить виноград* — виноград сыгу; **6.** *разг.* буып үтерү; *лиса давит кур* — төлке тавыкларны буып үтерә; **7.** *перен.* кысу, изү, җәберләү; *в капиталистическом обществе сильный всегда давит слабого* — капиталистик җәмгыятьтә көчле көчсезне һәрвакыт кыса; 8. *безл. разг.* кысу; *мне давит грудь* — минем күкрәгем кыса.

**ДАВИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* тапталу, тапталып үлү; изелү, сытылу, сыгылу; 2. (*чем-либо при глотании*) төелү, тыгылу, тамакка утыру, тамакка кадалу; **3.** *разг. фам.* комсызлану, ашыгып ашау; *не давись, ешь как следует* — комсызланма, рәтләп кенә аша; 4. *перен.* буылу (йөткерүдән, көлүдән); 5. *простореч.* (*повеситься*) асылыну, буылып үлү, асылынып үлү.

**ДА'ВКА** *ж. мн.* нет — 1. (*действие*) изү, сыту; 2. кысышу, этешү, этеш-төртеш; *при посадке на поезд началась давка* — поездга утырганда этеш-төртеш башланды.

**ДАВЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. (*действие*) басу; кысу; изү; 2. басым; *атмосферное давление* — атмосфера (һава) басымы; *давление крови* — кан басымы.

**ДАВНЕ'НЬКО** *нареч. разг.* — күптән, күптәннән (бирле), байтактан (бирле), хәтсездән.

**ДА'ВНИЙ** *книжн.* — күптәнге, әллә кайчангы.

**ДАВНИ'ШНИЙ** *разг.* — күптәнге, иске, элекке; *давнишний приятель* — иске дус, күптәнге дус.

**ДАВНО'** *нареч.* — күптән, әллә кайчан; күптәннән (бирле); *я давно его не видел* — мин аны күптәннән (бирле) күргәнем юк.

**ДАВНОПРОШЕ'ДШИЙ** *книж. устар.* — күптән үтеп киткән, күптән булган; әллә кайчангы, бик борынгы заманнардагы. ◇ **Давнопрошедшее время** *грам.* — күптән үткән заман.

**ДА'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. күптән булу, ... элек булу; *давность события* — вакыйганың күптән булуы; *десятилетняя давность* — ун ел элек булу; 2. *юр.* күптән булганлык; *наказанию не подлежит за давностью преступления* — җинаятьнең күптән булганлыгы сәбәпле җәзага тартылмый.

**ДАВНЫ'М-ДАВНО'** *нареч. разг.* — бик күптән, әллә кайчан ук, әллә кайчан; борын-борын заманда.

**ДА'ВЫВАТЬ** *многокр. простореч.* — биргәләү, биргәләштерү.

**ДАГЕСТА'НКА** *ж.* — дагстанлы хатынкыз.

**ДАГЕСТА'НЕЦ** *м.* — дагстанлы.

**ДАГЕСТА'НЦЫ** *мн.* — дагстанлылар, Дагстан халкы.

**ДА'ЖЕ** *частица* — хәтта; хәтта... да; *не только он, даже ты этого не можешь сделать* — ул гына түгел, хәтта син дә моны эшли алмыйсың.

**ДАК** *частица простореч.* — бит, ич; *дак я же говорил* — әйткән идем бит мин.

**ДАКТИЛИ'ЧЕСКИЙ** *лит.* — дактилик, дактиль белән язылган; *дактилические стихи* — дактилик шигырьләр (дактиль белән язылган шигырьләр).

**ДАКТИЛОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — дактилология (бармаклар ярдәмендә сөйләшү ысулы; бу юл белән телсез-чукраклар сөйләшәләр).

**ДА'КТИЛЬ** *м. лит.* — дактиль (басымы беренче иҗеккә төшә торган өч иҗекле шигырь стопасы).

**ДАЛАЙ-ЛА'МА** *м.* — далай-лама (Тибетта дин башлыгы һәм гражданнар власте башында торучы).

**ДА'ЛЕ** *нареч. поэт. устар.* — к. дальше.

**ДА'ЛЕЕ** *нареч. книж.* — 1. к. дальше; 2. аннары, аннан соң; *далее мы приступим к изучению вопроса* — аннан соң без мәсьәләне өйрәнүгә керешербез. ◇ **И так далее (и т. д.)** — һәм башкалар (һ. б.).

**ДАЛЁКИЙ** — 1. ерак; *далёкое путешествие* — ерак сәфәр; 2. ерактагы, ерак; *далёкий город* — ерактагы шәһәр; 3. күптән, ерак; *далёкое прошлое* — күптән үткән; *далёкое будущее* — ерак киләчәк; 4. *перен.* ят, чит; *они друг-другу далёкие люди* — алар бер-берсенә ят кешеләр; 5. *только с отриц. разг.* акылга сай, акыллы түгел; *он не очень далёкий человек* — ул бик үк акыллы кеше түгел, ул акылга сай кеше.

**ДАЛЕКО'** *нареч.* — 1. ерак; *я живу далеко от города* — мин шәһәрдән ерак торам; 2. ерак, күп вакыт бар; *до нового года ещё далеко* — яңа елга кадәр ерак (күп вакыт бар) әле; 3. бер дә, һич тә; *далеко не так* — бер дә (һич тә) алай түгел; *она далеко не красавица* — ул бер дә матур хатын түгел. ◇ **Мы засиделись далеко за полночь** — утыра торгач, төн урталары да үтеп китте. **Ему далеко за сорок** — ул кырыктан күптән узган инде. **Далеко зайти** *разг.* — чиктән ашу, тирәнгә китү. **Далеко ли до беды** *разг.* — бәла аяк астында йөри. **Далеко не уедешь или не уйдёшь** *разг.* — әллә кая китә алмассың, ерак бара алмассың. **Далеко пойти** — ерак китү (зур уңышларга ирешү, күпкә ирешү).

**ДАЛЕКО'-ДАЛЕКО'** *нареч.* — ерактаерақта, бик ерақта.

**ДАЛЁКОНЬКО** *нареч. разг. фам.* — шактый ерак; *далёконько вы живёте* — сез шактый ерақта торасыз икән.

**ДАЛЕ'ЧЕ** *нареч. простореч. обл.* — к. далеко.

**ДАЛЬ** *ж. мн.* нет — 1. *только ед. разг.* ерак җир; *я не пущу тебя одного в такую даль* — андый ерак җиргә мин сине үзеңне генә җибәрмим; 2.ераклык; *туманные дали* — томанлы ераклыклар. ◇ **Такая даль!** — бик ерак! *от дома до службы такая даль!* — өйдән эш урынына чаклы бик ерак! **Такую даль** — андый еракка; *трудно такую даль пешком идти* — андый еракка җәяү бару кыен.

**ДАЛЬНЕВИ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *науч.* — ерактан күрү (электромагнитик дулкыннар ярдәмендә сурәтләрне радио яки тимер чыбык аша еракка тапшыру һәм ерактан алу).

**ДАЛЬНЕВОСТО'ЧНЫЙ** *книж.* — Ерак Көнчыгыштагы, Ерак Көнчыгыш ...-ы; *Дальневосточные леса* — Ерак Көнчыгыш урманнары.

**ДАЛЬНЕ'ЙШИЙ** *книж.* — алдагы, киләчәктәге, моннан соңгы; *дальнейшие события* — моннан соңгы вакыйгалар. ◇ **В дальнейшем** — 1. (*в будущем*) киләчәктә, алда, алдагы көндә; 2. (*далее, ниже*) түбәндә, моннан соң.

**ДА'ЛЬНИЙ** — 1. ерак; ерактагы; *дальний путь* — ерак сәфәр, ерак юл; *дальние деревни* — ерактагы авыллар; 2. ерак; *дальний родственник* — ерак кардәш. ◇ **Без дальних слов** — сүзне озакка сузмыйча, озын сүзнең кыскасы.

**ДАЛЬНОБО'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *воен.* — ату ераклыгы, еракка атучанлык.

**ДАЛЬНОБО'ЙНЫЙ** *воен.* — ерактан ата торган; еракка ата торган.

**ДАЛЬНОВИ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — алдан күрү, алдан күрүчәнлек.

**ДАЛЬНОВИ'ДНЫЙ** — алдан күрүчән. ◇ **Дальновидный план** — алдагыны күздә тотып төзелгән план.

**ДАЛЬНОЗО'РКИЙ** — 1. ерактан яхшы күрүче; 2. якыннан күрмәүче, якыннан начар күрүче.

**ДАЛЬНОЗО'РКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1.ерак-

тан яхшы күрү; 2. (*недостаток в зрении*) якыннан күрмәү, якыннан начар күрү.

**ДАЛЬНОМЕ'Р** *м. физ.* — ераклыкны үлчәгеч.

**ДА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ераклык; *дальность расстояния* — араның ераклыгы.

**ДА'ЛЬНЫЙ** *обл.* — к. дальний.

**ДАЛЬТОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *мед.* — дальтонизм (кайбер төсләрне аера алмау авыруы).

**ДАЛЬТО'НИК** *мед.*, **ДАЛЬТОНИ'СТ** *м. книж.* — дальтоник, дальтонист (дальтонизм авыруы белән җәфаланучы кеше).

**ДА'ЛЬШЕ** — 1. ераграк, арырак; *я живу дальше, чем он* — мин аңа караганда ераграк торам; 2. *нареч.* аннары, аннан ары, аннан соң, шуннан соң; моннан ары, моннан соң; *а дальше что было?* — ә аннары нәрсә булды? 3. соңрак, түбәндәрәк; *в книге об этом говорится дальше* — китапта бу турыда соңрак сөйләнә; 4. *нареч. разг. фам.* артык; *я дальше не могу терпеть* — мин артык түзә алмыйм, артык чыдар хәлем калмады. ◇ **Пишите дальше** — язуны дәвам иттерегез.

**ДА'МА** *ж.* — 1. бикә, ханым (буржуаз-дворян җәмгыятьтә); 2. дама (а. танцыда кавалер белән биюче хатын-кыз; б. хатын-кыз рәсеме төшерелгән карта). ◇ **Дама сердца** *шутл.* — сөйгән яр, җанкай, җанаш. **Классная дама** — революциягә кадәр кызлар өчен булган уку йортында надзирательница.

**ДА'МБА** *ж.* — дамба (су басудан саклау, су тоту яки су баса торган урыннарга юл салу өчен өелгән балчык һәм таш өеме).

**ДА'МКА** *ж.* — дамка (шашка уенында).

**ДАМО'КЛОВ МЕЧ** *перен.* — өзлексез хәвеф-хәтәр, өзлексез куркыныч.

**ДА'МСКИЙ** — хатын-кызлар ...-ы; *дамское пальто* — хатын-кызлар пальтосы. ◇ **Дамский портной** — хатын-кызлар киеме тегүче.

**ДА'ННИК** *м. книж. истор.* — ясак түләүче.

**ДА'ННИЧЕСКИЙ** *истор.*—ясак түләү...-ы; *даннические отношения* —ясак түләү мөнәсәбәтләре.

**ДА'ННОСТЬ** *ж. книж.*— объектив чынбарлык булу, бирелгән булу, барлык.

**ДА'ННЫЕ** *мн. книж.* — 1. мәгълүматлар; *нет достаточных данных для вывода* — нәтиҗә ясар өчен җитәрлек мәгълүматлар юк; 2. мөмкинлекләр; *у него имеются все данные для отличной учёбы* — отличнога уку өчен аның бөтен мөмкинлекләре бар; 3. дәлилләр, нигезләр; *нет достаточных данных для возбуждения уголовного преследования* — җинаятьтә гаепләп эш кузгату өчен җитәрлек дәлилләр юк. ◇ **Хорошие слуховые данные** — музыкага сәләтлелек. **Хорошие голосовые данные** — тавышы яхшы булу.

**ДА'ННЫЙ** *книж.* — 1. бирелгән, биргән; *данное обещание я выполняю* — биргән вәгъдәмне мин үтим; 2. шушы, бу, хәзерге, әлеге; *в данную минуту* — шушы минутта; *данный случай* — бу вакыйгада; *в данный момент* — хәзерге моментта.

**ДАНТИ'СТ** *м.*— 1. *дореволь.* дантист (махсус белеме булмаган теш врачы); 2. *пренебр.* авыз җимерүче, теш коючы (үзенә буйсынган кешеләрне кыйнаучы).

**ДАНЬ** *ж.*—1. *книж. истор.* ясак; 2. *перен.* тиешле бәя, хөрмәт, ихтирам.

**ДАР** *м. книж.* — 1. бүләк; *принести в дар* — бүләк итеп бирү; 2. *только ед.* талант, сәләт, сәләтлелек; *дар слова* — сөйләү сәләте, сөйләү таланты. ◇ **Дары данайцев** *перен.* — яман уй белән бирелгән бүләк.

**ДАРВИНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — дарвинизм, Дарвин тәгълиматы.

**ДАРВИНИ'СТ** *м.*, **ДАРВИНИ'СТКА** *ж.*— дарвинчы, дарвинизм тарафдары.

**ДАРЁНЫЙ** *разг.* — бүләк ителгән, бүләк итеп бирелгән. ◇ **Дарёному коню в зубы не смотрят** — биргәннең битенә карамыйлар.

**ДАРИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ДАРИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. офиц.* — бүләк итүче, бүләк итеп бирүче.

**ДАРИ'ТЬ** *несов.* — бүләк бирү, бүләк итеп бирү. ◇ **Дарить улыбкой** — елмаеп карау. **Дарить вниманием кого-л.** — кемгә дә булса игътибар күрсәтү. **Дарить свободу** — азат итү.

**ДАРМОЕ'Д** *м.*, **ДАРМОЕ'ДКА** *ж. разг. презр.* — әрәм тамак, бушка ашап ятучы, кеше җилкәсен кимерүче.

**ДАРМОЕ'ДНИЧАТЬ** *несов. разг. презр.*— кеше җилкәсендә яшәү, кеше җилкәсен кимерү.

**ДАРМОЕ'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. презр.* — әрәм тамаклык.

**ДАРОВА'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. даровать; 2. талант, сәләт; *природное дарование необходимо развивать* — табигый сәләтне үстерергә кирәк.

**ДАРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. книж. поэт.*: **даровать свободу** — азат итү; **даровать жизнь** — үлем җәзасыннан коткару.

**ДАРОВИ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — талантлылык, сәләтлелек.

**ДАРОВИ'ТЫЙ** — талантлы, сәләтле.

**ДАРОВО'Й** *разг.* — 1. (*бесплатный*) бушлай алынган, бушлай бирелгән, түләүсез; 2. *простореч.* (*дарёный*) бүләк итеп бирелгән.

**ДАРОВЩИ'НА, ДАРОВЩИ'НКА** *ж. мн.* нет, *разг. фам.*— бушлай килгән әйбер; *он любит даровщину* — ул бушлай килгән әйберне ярата. ◇ **На даровщину** — кеше хисабына.

**ДА'РОМ** *нареч. разг.* — 1. (*бесплатно*) буш, бушлай, бушка, түләүсез, акчасыз гына; 2. (*дёшево*) арзан, очсыз; 3. кирәкмәскә, файдасызга, әрәмгә, юкка, бушка; *весь день даром пропал* — бөтен көн әрәмгә үтте. ◇ **Даром что** *простореч.* — ...-га карамастан, ... булса да; *даром что старый, а глупей ребёнка* — карт булуына карамастан, баладан да акылсызрак. **Это тебе даром не пройдёт** — 1. бу сиңа шома гына үтеп китмәс; 2. син моның җәзасын күрерсең әле.

**ДА'РСТВЕННЫЙ: дарственная запись** *юр.* — бүләк язуы, бүләкләү кәгазе (бүләк итеп бирелгән әйберләр язылган документ).

**ДА'ТА** *ж. книж.* — дата (бирәр вакыйганың булу, үтәлү вакыты; документның язылу вакыты).

**ДА'ТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ** *грам.* — дательный падеж.

**ДАТИ'РОВАННЫЙ** *книж.* — дата куелган, датасы куелган, даталы.

**ДАТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. даталау, датасын (дата) кую, датасын күрсәтү (вакыйганың яки эшнең булу, үтәлү вакытын көне, ае, елы белән күрсәтү); 2. берәр фактның датасын билгеләү.

**ДАТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. даталану, дата белән билгеләнү; 2. *страд.* датасы куелу, датасы күрсәтелү.

**ДА'ТОЧНЫЙ** *истор.* — ясак түләргә тиешле; *даточные люди* — ясак түләргә тиешле кешеләр.

**ДА'ТСКИЙ** —1. даниялеләр ...-ы; *датский язык* — даниялеләр теле; 2. Дания ...-ы; *датское государство* — Дания дәүләте.

**ДАТЧА'НЕ** *м. мн.*—даниялеләр, Дания халкы.

**ДАТЧА'НИН** *м.* — данияле.

**ДАТЧА'НКА** *ж.* — данияле хатын-кыз.

**ДАТЬ** *сов.* — 1. бирү; 2. рөхсәт итү; *дайте мне сказать несколько слов*—миңа берничә сүз әйтергә рөхсәт итегез; 3. оештыру; *дать обед*—мәҗлес оештыру. ◇ **Дать знать** —белдерү, хәбәр итү. **Дать понять**— сиздерү, аңлату. **Я тебе дам** *простореч. фам.* — мин синең кирәгеңне бирермен. **Ни дать, ни взять**—к. взять. **Дать клятву** — ант итү. **Дать течь** —агу, тишелү. **Дать трещину**—ярылу. **Дать начало**— башланып китү. **Дай, я сам пойду** — әйдә, үзем барыйм әле. **Дать тягу** *разг. фам.* — качып китү, шылу. **Дать маху** *разг.* — ялгышу.

**ДА'ТЬСЯ** *сов.*: **я не дамся в обман** — мин үземне алдатмам; **дался, далась, далось** *ему, тебе* — тапкан(сың) инде; *далось тебе это кино: только туда и ходишь*— тапкансың инде, бар белгәнең кино: шунда йөрүне генә беләсең.

**ДА'ФНИЯ** *ж. зоол.* — дафния, су борчасы (түбән төзелешле кысла).

**ДА'ЧА** I ж. — 1. бирү; *дача показания*— показание бирү; 2. бирем; *кормовая дача* азык бирeме.

**ДА'ЧА** II *ж.* — дача (җәй көне тору һәм ял итү өчен шәһәр читендә салынган өй).

**ДА'ЧА** III *ж.* — дача, урман участогы; *лесная дача* — урман дачасы.

**ДАЧЕВЛАДЕ'ЛЕЦ** *м.*, **ДАЧЕВЛАДЕ'ЛИЦА** *ж. офиц.* — дача хуҗасы.

**ДА'ЧНИК** *м.*, **ДА'ЧНИЦА** *ж.* — дачада торучы.

**ДА'ЧНЫЙ**—1. дача ...-ы; *дачная жизнь*— дача тормышы; 2. дачный; *дачный поезд* — дачный поезд.

**ДАЯ'НИЕ** *ср. церк. книж.* — иганә, сәдака.

**ДВА** — ике. ◇ **Ни два, ни полтора** *разг.* — икеле-микеле. **В двух словах** — кыска гына итеп, бер-ике сүз белән. **В два счёта** *просторeч.* — бик тиз, хәзер үк, күз ачып йомганчы. **В двух шагах** *разг.* — бик якын, яп-якын, ике адымда гына.

**ДВАДЦАТИГРА'ННЫЙ** *мат.* — егерме кырлы.

**ДВАДЦАТИДЮЙМО'ВЫЙ** — егерме дюймлы.

**ДВАДЦАТИЛЕ'ТИЕ** *ср.* — 1. (*годовщина*) егерме еллык; 2. (*срок*) егерме ел.

**ДВАДЦАТИЛЕ'ТНИЙ** — 1. егерме еллык; *двадцатилетняя дружба* — егерме еллык дуслык; 2. егерме яшьлек; *двадцатилетний юноша* — егерме яшьлек егет.

**ДВАДЦАТИПЯТИЛЕ'ТИЕ** *ср.*— 1. егерме биш еллык; *двадцатипятилетие революции* — революциянең егерме биш еллыгы; 2. егерме биш ел; *он проработал на заводе целое двадцатипятилетие*—ул заводта егерме биш ел буена эшләгән.

**ДВАДЦАТИПЯТИЛЕ'ТНИЙ** — 1. егерме биш еллык; *двадцатипятилетний юбилей* — егерме биш еллык юбилей; 2. егерме биш яшьлек; *мой двадцатипятилетний сын*— минем егерме биш яшьлек улым.

**ДВАДЦА'ТЫЙ** — егерменче; *двадцатые годы* — егерменче еллар. ◇ **Люди двадцатого числа** *дореволю. ирон.*— чиновниклар (һәр айның 20 нче числосында жалованье алуны көткәнлекләре өчен шулай аталганнар).

**ДВА'ДЦАТЬ** *ж.*— егерме.

**ДВАДЦАТЬЮ'** *нареч.*— егерме тапкыр, егерме җирдә.

**ДВА'ЖДЫ** *нареч.*— 1. ике тапкыр, ике мәртәбә, ике кат; *я дважды был у него* — мин аңарда ике тапкыр булдым; 2. *мат.* ике тапкыр, ике җирдә; *дважды два — четыре* — ике җирдә икең — дүрт.

**ДВЕ** *ж.* —ике; *две улицы* — ике урам.

**ДВЕНАДЦАТИГРА'ННЫЙ** *мат.*— унике кырлы.

**ДВЕНАДЦАТИПЕ'РСТНЫЙ: двенадцатиперстная кишка** *анат.* — уникеилле эчәк.

**ДВЕНА'ДЦАТЫЙ** — уникенче.

**ДВЕНА'ДЦАТЬ** *ж.*— унике.

**ДВЕ'РКА** *ж.*— к. дверца.

**ДВЕРНО'Й** — ишек ...-ы; *дверной замок* — ишек йозагы.

**ДВЕ'РЦА** *ж.*— 1. ишек, кечкенә ишек; *дверцы автомобиля* — автомобиль ишекләре; 2. капкач; *печные дверцы* — мич капкачлары.

**ДВЕРЬ** *ж.*— ишек. ◇ **Показать на дверь** *разг.*— куып чыгару. **При закрытых дверях** — үзара гына, чит кешеләрне кертмичә. **Двери на запор** *от кого*, или **закрыть двери дома** *для кого устар.* — (аның өчен) ишек ябык. **Ломиться в открытую дверь** *разг.*— ачык ишекне кагу (һәркемгә билгеле булган нәрсәне исбат итү).

**ДВЕ'СТИ** — ике йөз.

**ДВИ'ГАТЕЛЬ** *м.* — 1. *тех.* двигатель; 2. *перен. книж.* этәргеч, этәрүче, алга җибәрүче, үстерүче (көч); *университет является двигателем науки и культуры* —

университет фән һәм культураны алга җибәрүче көч булып тора.

**ДВИ'ГАТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — хәрәкәткә китерүче, хәрәкәтләндерүче; *двигательные нервы* — хәрәкәткә китерүче нервлар.

**ДВИ'ГАТЬ** *несов.* — 1. этү, этәрү, күчерү, йөртү; *двигать мебель* — мебельне күчерү; 2. хәрәкәтләндерү, хәрәкәткә китерү, йөртү; *пружина движет часовой механизм* — пружина сәгать механизмын хәрәкәткә китерә; 3. кыймылдату, селкетү; *двигать пальцами* — бармакларны кыймылдату; 4. алып бару, юнәлдерү; *двигать войска на неприятеля* — гаскәрләрне дошманга каршы алып бару; 5. *перен. книж.* алга җибәрү, алга этәрү, үстерү; *двигать науку вперёд* — фәнне алга җибәрү; 6. *перен.* күтәрү; *двигать по службе* — хезмәт буенча күтәрү; 7. илһамландыру, рухландыру; *им движет чувство патриотизма* — аны патриотизм хисе илһамландыра.

**ДВИ'ГАТЬСЯ** *несов.* — 1. бару, хәрәкәт итү, йөрү; *двигаться вперёд* — алга бару; 2. кузгалу, кузгалып китү, китү; *пора нам двигаться* — безгә кузгалырга вакыт; 3. *перен.* кыймылдау, селкенү, кузгалу; *не двигайся!* — (урыныңнан) кузгалма! 4. *разг.* үсү, күтәрелү, алга үрләү; *двигаться по службе* — хезмәт буенча күтәрелү; 5. *страд.* этәрелү, күчерелү, йөртелү; хәрәкәткә китерелү; алга җибәрелү. ◇ **Земля движется вокруг своей оси** — җир үз күчәре тирәсендә әйләнә.

**ДВИЖЕ'НЕЦ** *м.* — тимер юл эшчесе, трамвай эшчесе (поезд яки трамвай йөрешен тәртипкә салып торучы кеше).

**ДВИЖЕ'НИЕ** *ср.* — 1. хәрәкәт; *рабочее движение* — эшчеләр хәрәкәте; 2. йөреш; *движение поездов* — поездлар йөреше; 3. йөрү; *после десяти часов движение прекращается* — сәгать уннан соң йөрү туктала; 4. күтәрелү; *движение по службе* — хезмәт буенча күтәрелү; 5. сан үзгәрү; *движение народонаселения* — халык саны үзгәрү; 6. барыш, агым; *движение событий* — вакыйгаларның барышы. ◇ **Вольные движения** *спорт.* — ирекле хәрәкәтләр.

**ДВИ'ЖИМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *юр.* — күчмә милек.

**ДВИ'ЖИМЫЙ** *книж.* — 1. күчмә, күчерелә торган; *движимое имущество* — күчмә милек (өй җиһазлары); 2. рухланган, дәртләнгән; *движимый чувством любви к Родине* — Ватанга мәхәббәт хисе белән рухланган.

**ДВИ'ЖУЩИЙ** *книж.* — юнәлеш бирүче, юнәлдергеч; *движущие силы революции* — революциянең юнәлеш бирүче көчләре.

**ДВИ'НУТЬ** *сов.* — 1. к. двигать 1, 3, 4, 5; 2. *простореч.* кундыру, тондыру, бирү, ямау; *он его двинул в ухо* — ул аның колак төбенә бирве тондырды.

**ДВИ'НУТЬСЯ** *сов.* — 1. чыгу; *двинуться в путь* — юлга чыгу; *двинуться в поход* — походка чыгу; 2. кузгалу, кузгалып китү; *он не двинулся с места* — ул урыныннан да кузгалмады; *толпа двинулась* — халык төркеме кузгалып китте.

**ДВО'Е** — 1. икәү, икесе; *их было двое* — алар икәү иде; 2. ике; *двое детей* — ике бала; *двое суток* — ике тәүлек. ◇ **На своих двоих** *шутл.* — тәпи-тәпи, җәяүләп.

**ДВОЕВЛА'СТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — ике властьлылык.

**ДВОЕДУ'ШИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — икейөзлелек.

**ДВОЕДУ'ШНИЧАТЬ** *несов.* — икейөзләләнү.

**ДВОЕДУ'ШНЫЙ** — икейөзле.

**ДВОЕЖЕ'НЕЦ** *м. книж. офиц.* — ике хатынлы.

**ДВОЕЖЕ'НСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. офиц.* — ике хатын белән тору, ике хатынлылык.

**ДВОЕМУ'ЖИЕ** *ср. мн.* нет, *устар.* — ике ирлелек, ике ир белән тору.

**ДВОЕТО'ЧИЕ** *ср.* — ике нокта.

**ДВО'ЕЧНИК** *м.*, **ДВО'ЕЧНИЦА** *ж.* — икеле алучы, икеле билгесе алучы (өлгермәүче укучы).

**ДВОЕ'ШКА** *ж.* — 1. куш төшле (мәсәлән, чикләвек); 2. *только мн. простореч.* игезәкләр.

**ДВОИ'ТЬ** — 1. (*раздваивать*) икегә яру; 2. (*вторично вспахивать*) икенче кат сөрү; кабат сөрү.

**ДВОИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. ике булып күренү; *у меня двоится в глазах* — минем күземә ике булып күренә; 2. *страд.* икегә ярылу; икенче кат сөрелү.

**ДВО'ЙКА** *ж.* — 1. *разг.* (*цифра*) ике, икеле цифра; 2. икеле, икеле билгесе; *он получил двойку* — ул икеле билгесе алган; 3. (*в карте*) икелек; 4. *спорт.* ике ишкәкле көймә. ◇ **Я ехал сегодня на двойке** — мин бүген икенче номерлы трамвайда (автобуста) килдем.

**ДВОЙНИ'К** *м.* — 1. төстәш (тышкы кыяфәтләре белән бер-берсенә бик нык охшаган ике кешенең берсе); 2. игез балаларның берсе.

**ДВОЙНО'Й** — 1. икеләтә; *двойной расход* — икеләтә расход; 2. ике катлы; *двойные рамы* — ике катлы рамнар; 3. ике иңле; *двойная материя* — ике иңле материя; 4. *перен.* к. двойственный. ◇ **Двойная игра** — икейөзлелек, мәкерлелек.

**ДВО'ЙНЯ** *ж.* — игез, игезәк.

**ДВОЙНЯ'ШКА** *ж. разг.* — к. двойня.

**ДВО'ЙСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. икеләнүчәнлек; 2. *перен.* икейөзлелек, мәкерлелек.

**ДВО'ЙСТВЕННЫЙ** — 1. ике төрле, икеле, ике яклы, икеле-микеле. 2. икейөзле, мәкерле; *двойственный характер* — икейөзле характер. ◇ **Двойственное число** *лингв.* — икелек саны (берлек-күплек белән генә түгел, икелек белән дә төрләнү).

**ДВОЙЧА'ТКА** *ж. обл.* — куш (чикләвек, кыяр һ. б.).

**ДВОР** *м.* — 1. ишек алды; *на дворе* — ишек алдында; 2. йорт (өй һәм каралтылар белән бергә крестьян хуҗалыгы); *в де-*

*ревне имеется сто дворов* — авылда йөз йорт (хуҗалык) бар; **3.** тыш; *на дворе холодно* — тышта салкын; **4.** *истор.* патша сарае, сарай; *министр двора* — сарай министры; **5.** сарай халкы (патша һәм аңа якын кешеләр; патша сараена хезмәт күрсәтүчеләр). ◇ **Прийтись не ко двору** (*о животных*) — тес бирмәү, килешмәү; (*о человеке*) ошамау, артык булу. **Постоялый двор** — постоялый двор. **Скотный двор** — терлек абзары, терлек утары. **Конный двор** — атлар утары. **Монетный двор** — монетный двор (акча суга торган җир).

**ДВОРЕ'Ц** *м.* — дворец, сарай; *дворец труда* — хезмәт сарае.

**ДВОРЕ'ЦКИЙ** *устар.* — баш лакей (байлар өендәге баш хезмәтче).

**ДВО'РНИК** *м.* — дворник (ишек алларын һәм йорт тирәләрен карап чистартып торучы).

**ДВО'РНИЦКАЯ** — дворник бүлмәсе, дворник өе.

**ДВО'РНИЦКИЙ** — дворник ...-ы; *дворницкая работа* — дворник эше.

**ДВО'РНИЧИХА** *ж. простореч.* — **1.** дворник хатыны; **2.** дворник хатын.

**ДВО'РНЯ** *ж. мн.* нет, *собир. истор.* — йорт хезмәтчеләре (крепостное право заманында алпавыт йортында эшләүчеләр).

**ДВОРНЯ'ГА, ДВОРНЯ'ЖКА** *ж.* — гади эт, йорт эте.

**ДВОРО'ВЫЙ** — **1.** йорт ...-ы; *дворовая собака* — йорт эте; **2.** алпавыт йортындагы хезмәтче; *дворовая девка* — алпавыт йортындагы хезмәтче кыз; **3.** *в знач. сущ.* алпавыт йортындагы хезмәтче; *музыкант из дворовых* — алпавыт хезмәтчеләре арасыннан чыккан музыкант.

**ДВОРОХОЗЯ'ЙСТВО** *ср.* — йорт хуҗалыгы, аерым крестьян хуҗалыгы.

**ДВОРЦО'ВЫЙ** — сарай ...-ы; *дворцовая архитектура* — сарай архитектурасы.

**ДВОРЯ'НЕ** *мн.* — дворяннар.

**ДВОРЯНИ'Н** *м.* — дворян.

**ДВОРЯ'НКА** *ж.* — дворянка (дворян хатыны, дворян кызы).

**ДВОРЯ'НСКИЙ** — дворян ...-ы; дворяннар ...-ы; *дворянский сын* — дворян улы; *дворянский банк* — дворяннар банкысы.

**ДВОРЯ'НСТВО** *ср. мн.* нет — **1.** дворяннар сословиесе; **2.** *собир.* дворяннар.

**ДВОРЯ'НЧИК** *м. пренебр.* — дворян кисәге, дворян; *захудалый дворянчик* — өтек дворян.

**ДВОЮ'РОДНЫЙ** — туганнан туган, тудыка (аталары яки аналары бертуган кешеләр); *двоюродный брат* — туганнан туган абый (эне).

**ДВОЯ'КИЙ** *книж.* — ике төрле; ике яклы, ике яклап; *двоякое значение* — ике төрле мәгънә; *двоякая польза* — ике яклап файда.

**ДВОЯ'КО** *нареч.* — **1.** ике төрле; *его слова можно понимать двояко* — аның сүзләрен ике төрле аңларга мөмкин; **2.** ике төрле юл белән; *задачу можно решить двояко* — мәсьәләне ике төрле юл белән чишәргә мөмкин.

**ДВОЯКОВО'ГНУТЫЙ** *физ.* — ике ягы да батынкы; *двояковогнутое стекло* — ике ягы да батынкы пыяла.

**ДВОЯКОВЫ'ПУКЛЫЙ** *физ.* — ике ягы да кабарынкы; *двояковыпуклое стекло* — ике ягы да кабарынкы пыяла.

**ДВУБО'РТНЫЙ** — ике капламалы, ике якка да төймәләнә торган; *двубортное пальто* — ике якка да төймәләнә торган пальто.

**ДВУГЛА'СНЫЙ** *лингв.* — к. дифтонг.

**ДВУГО'РБЫЙ** — ике өркәчле (дөя).

**ДВУГРА'ННЫЙ** *мат.* — ике кырлы.

**ДВУГРИ'ВЕННЫЙ** *м. разг.* — егерме тиен; егерме тиенлек көмеш акча.

**ДВУЖИ'ЛЬНЫЙ** *разг.* — чыдам, нык, таза, көчле.

**ДВУЗНА'ЧНЫЙ** *мат.* — ике урынлы; *двузначное число* — ике урынлы сан.

**ДВУКЛА'ССНЫЙ** *устар.* — ике классы (мәктәп).

**ДВУКО'ЛКА** *ж. разг. спец.* — двуколка ике тәгәрмәчле арба.

**ДВУКО'ННЫЙ** — ике атлы, ике ат жигелә торган.

**ДВУКРА'ТНЫЙ** *книж.* — ике кат, ике тапкыр, ике мәртәбә.

**ДВУЛЕ'ТНИЙ** *бот.* — ике еллык, ике ел яши торган (үсемлек).

**ДВУЛЕ'ТНИК** *м. бот.* — ике еллык үсемлек, ике ел яши торган үсемлек.

**ДВУЛИ'КИЙ:** **двуликий Янус** *книж.* — икейөзле кеше.

**ДВУЛИ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — икейөзлелек.

**ДВУЛИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. двуличие.

**ДВУЛИ'ЧНЫЙ** — икейөзле, мөнафыйк.

**ДВУМЕ'СТНЫЙ** *книж. устар.* — к. двухместный.

**ДВУНО'ГИЙ** *книж.* — ике аяклы. ◇ **Двуногое животное** *бран. презр.* — хайван (кеше турында).

**ДВУО'СНЫЙ** — ике күчәрле.

**ДВУПО'ЛЫЙ** — **1.** *биол.* ике женесле, кызтәкә, хонса; **2.** *бот.* ике женесле (аталык һәм аналык агзалары бер чәчәктә булган үсемлек).


**ДОУ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. доучить.

**ДОУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— к. доучиться.

**ДОУЧИ'ТЬ** *сов.* — **1.** укытып җиткерү; өйрәтеп җиткерү; **2.** ...-га кадәр өйрәнү, өйрәнеп бетерү, ...-га кадәр ятлау, ятлап бетерү; *доучить урок до конца* — дәресләрне ахырына кадәр өйрәнү; *он не доучил трёх строчек в басне* — ул мәсәлнең өч юлын ятлап бетермәгән.

**ДОУЧИ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** укып бетерү; өйрәнеп бетерү; укуны тәгәлләү; *он поступил в институт доучиться* — укуын тәгәлләү өчен ул институтка керде; **2.** өйрәнеп җитү; *немного осталось доучиться токарному делу* — токарьлык эшенә өйрәнеп җитәргә аз гына калды.

**ДОХА'** *ж.*— доха (эче-тышы мехлы тун).

**ДОХЛЕБА'ТЬ** *сов. просторен.* — ашап бетерү (сыек ашны).

**ДОХЛЁБЫВАТЬ** *несов. просторен.*— к. дохлебать.

**ДОХЛЁБЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— ашалып бетү (сыек ашамлык турында).

**ДО'ХЛЫЙ** — **1.** (*о животных*) үлгән; **2.** *просторен. вульг.* (*хилый*) бетерешкән, хәлсез.

**ДОХЛЯ'ТИНА** *ж. мн.* нет, *просторен.*— **1.** (*труп павшего животного*) үләксә; (*собир. падаль*) үләксәләр; **2.** *м.* и *ж. презрит.* (*хилый человек*) бетерешкән кеше, хәлсез кеше, чирләшкә кеше, үләксә.

**ДО'ХНУТЬ** *несов.* — үлү; кырылу (хайваннар турында гына). ◇ **Рассказывает так, что мухи дохнут** *разг. ирон.*— чиктән тыш күңелсез итеп сөйли.

**ДОХНУ'ТЬ** *сов. однокр.*— **1.** сулап алу; **2.** *перен.* исеп кую; *дохнул слабый ветерок*— йомшак кына җил исеп куйды. ◇ **Не сметь дохнуть** *разг.*— тын да чыгармау, шылт та итмәү.

**ДОХО'Д** *м.*— доход, килер.

**ДОХОДИ'ТЬ** *несов.*— к. дойти. ◇ **Не доходя** — барып җитмәстән, бирерәк, бераз бире. **Руки не доходят** *разг.*— кул тими, вакыт юк.

**ДОХО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — доходлылык, доход бирүчәнлек.

**ДОХО'ДНЫЙ** — доходлы; файдалы, табышлы.

**ДОХО'ДЧИВО** *нареч. разг.* — аңлаешлы итеп, төшенерлек итеп.

**ДОХО'ДЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — аңлаешлылык.

**ДОХО'ДЧИВЫЙ** *разг.*— аңлаешлы.

**ДОЦВЕСТИ'** *сов.*— чәчәк атып бетерү.

**ДОЦВЕТА'ТЬ** *несов.*— к. доцвести.

**ДОЦЕ'НТ** *м.*— доцент (югары уку йортларында кандидатлык дәрәҗәсе булган укытучыларга бирелә торган гыйльми звание).

**ДОЦЕНТУ'РА** *ж. мн.* нет — **1.** *книж.* доцентлык вазыйфасы, доцентлык дәрәҗәсе; **2.** *собир. разг.* доцентлар.

**ДОЧЕ'РНИЙ** — кызының, кызымның, кызыңның.

**ДОЧЕРТИ'ТЬ** *сов.*— сызып бетерү, сызып җиткерү.

**ДОЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов.*— к. дочертить.

**ДОЧЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сызылып бетү.

**ДОЧЕСА'ТЬ** *сов.*— тарап бетерү.

**ДОЧЕ'СТЬ** I *сов. устар.*— к. дочитать.

**ДОЧЕ'СТЬ** II *сов. устар.*— к. досчитать.

**ДОЧЁСЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. дочесать

**ДОЧИ'НИВАТЬ** *несов. разг.*— к. дочинить.

**ДОЧИ'НИВАТЬСЯ** *несов. страд., разг.* — к. дочиняться.

**ДОЧИНИ'ТЬ** *сов. разг.* — төзәтеп бетерү; ямап бетерү.

**ДОЧИНЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. дочинить.

**ДОЧИНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд., разг.* — төзәтелеп бетү; ямалып бетү.

**ДО'ЧИСТА** *нареч.* — **1.** (*до полной чистоты*) чистарганчы, тазарганчы, чистарткანчы, чип-чиста булганчы; **2.** *перен. разг.* бернәрсә дә калдырмыйча, кырып-себереп, тап-такыр итеп; *съесть всё дочиста* — бернәрсә калдырмыйча ашап бетерү.

**ДОЧИ'СТИТЬ** *сов.* — чистартып бетерү; әрчеп бетерү; (*о самоваре*) агартып бетерү.

**ДОЧИТА'ТЬ** *сов.* — укып бетерү, ...-га кадәр уку.

**ДОЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. дочитать.

**ДОЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд., разг.* — укылып бетү.

**ДОЧИЩА'ТЬ** *несов.* — к. дочистить.

**ДОЧИЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — чистартылып бетү, әрчелеп бетү; агартылып бетү.

**ДО'ЧКА** *ж.* — к. дочь.

**ДОЧЬ** *ж.* (*мн. дочери*) — кызы(м, н).

**ДОШАГА'ТЬ** *сов., разг. шутл.* — атлап барып житү, атлап килеп житү.

**ДОШВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — **1.** к. дошвырнуть; **2.** к. дошвырять.

**ДОШВЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд., разг.* — ыргытылып бетү; ыргытылып житкерелү.

**ДОШВЫРНУ'ТЬ** *сов. разг.* — ыргытып житкерү; атып житкерү.

**ДОШВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — ыргытып бетерү.

**ДОШИВА'ТЬ** *несов.* — к. дошить.

**ДОШИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тегелеп бетү.

**ДОШИ'ТЬ** *сов.* — тегеп бетерү.

**ДОШКО'ЛЬНИК** *м.*, **ДОШКО'ЛЬНИЦА** *ж.* — **1.** (*ребёнок*) мәктәпкәчә яшьтәге бала; **2.** (*воспитатель*) мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүче педагог.

**ДОШКО'ЛЬНЫЙ** — мәктәпкәчә; *дошкольное воспитание* — мәктәпкәчә тәрбия.

**ДО'ШЛЫЙ** *простореч.* — булган, күпне күргән; хәйләкәр; житез, аңлы.

**ДОЩА'НИК** *м.* — яссы төпле көймә.

**ДОЩАНО'Й** — тактадан ясалган.

**ДОЩА'ТЫЙ** — такта ...; *дощатый забор* — такта койма.

**ДОЯ'РКА** *ж. с.-х.* — сыер савучы хатын.

**ДРАГОМА'Н** *м.* — тәрҗемәче (Европа дәүләтләренең көнчыгыш илләрдәге посольстволарында эшләүче тәрҗемәче).

**ДРАГОЦЕ'ННОСТЬ** *ж.* — кыйммәтле әйбер.

**ДРАГОЦЕ'ННЫЙ** — **1.** кыйбатлы, кыйммәтле, югары бәяле; *драгоценная ваза* — кыйммәтле ваза; **2.** кадерле, хөрмәтле; *драгоценный друг* — кадерле дус. ◇ **Драгоценные камни** — асыл ташлар.

**ДРАГУ'НЫ** *мн. воен. дореввол.* — драгуннар (революциягә кадәр кавалерия частьларының бер төре).

**ДРАЖА'ЙШИЙ** *устар.* — кадерле, хөрмәтле, мөхтәрәм. ◇ **Дражайшая половина моя** *шутл. устар.* — хәләл җефетем, хатыным.

**ДРАЗНИ'ЛКА** *ж. разг.* — үчекләү такмагы (мәсәлән, Монасыйп, тавыкларга ярма сип, анда сипмә, монда сип...).

**ДРАЗНИ'ТЬ** *несов.* — **1.** (*передразнивать*) үртәү, үчекләү, мыскыллау, ирештерү; (*раздражать*) җилкендерү; **3.** кузгату; *дразнить аппетит* — аппетитны кузгату.

**ДРАЗНИ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — үртәшү, үчекләшү.

**ДРА'КА** *ж.* — сугыш, сугышу, кыйнаш, кыйнашу.

**ДРАКО'Н** *м. миф.* — аждаһа. ◇ **Драконовы законы** — үтә каты законнар.

**ДРА'МА** *ж. книж.* — **1.** драма (сәхнә әсәренең бер төре); **2.** *перен.* кайгылы вакыйга, авыр кичереш, бәхетсезлек; *семейная драма* — семьядагы авыр кичерешләр.

**ДРАМАТИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — драмалаштыру, сәхнәләштерү (нинди дә булса бер әсәрне сәхнәдә уйнау өчен үзгәртеп драма формасында язу).

**ДРАМАТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд., книж.* — драмалаштырылу, сәхнәләштерелү.

**ДРАМАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — **1.** драматизм (вакыйгаларның, хәлләрнең киеренкелеге); **2.** киеренкелек, авырлык.

**ДРАМАТИ'ЧЕСКИЙ** — **1.** драма ...-ы; *драматический театр* — драма театры; **2.** ясалма, кыланчык; *драматические жесты* — ясалма (кыланчык) хәрәкәтләр; **3.** авыр; *драматический случай* — авыр вакыйга.

**ДРАМАТИ'ЧНЫЙ** — к. драматический 3.

**ДРАМАТУ'РГ** *м.* — драматург (драма әсәрләре язучы).

**ДРАМАТУРГИ'ЧЕСКИЙ** — драматургия ...-ы; *драматургические произведения* — драматургия әсәрләре.

**ДРАМАТУРГИ'Я** *ж. мн.* нет — **1.** драматургия (а. драма әсәрләре язу теориясе һәм сәнгате; б. драма әсәрләре иҗат итү эшчәнлегенә хас булган үзенчәлекләр, характерлы яклар); **2.** *собир.* драма әсәрләре, драматик әсәрләр.

**ДРАМКРУЖО'К** *м.* — драмтүгәрәк.

**ДРА'НКА** *ж.* — дранча.

**ДРА'НОЧНЫЙ** — дранча ...-ы; *драночная клетка под штукатуркой* — штукатура астындагы дранча челтәре.

**ДРА'НЫЙ** *простореч.* — **1.** ертык, сәләмә, алама; **2.** тузган, таушалган.

**ДРАНЬ** *ж. мн.* нет — к. дранка.

**ДРАП** *м. мн.* нет — драп (калын сукно сорты).

**ДРАПАНУ'ТЬ** *сов. вульг. презр.* — табан ялтырату, үкчә күтәрү, шылу, таю.

**ДРАПИРОВА'ТЬ** *несов.* — драпировать итү (**1.** бүлмәне паласлар, пәрдәләр белән бизәү; **2.** кемгә дә булса киң кием, плащ кидерү, бөркәндерү).

**ДРАПИРО'ВКА** *ж.* — **1.** к. драпировать 1; **2.** драпировка (тәрәзәләргә, ишекләргә

зиннәт өчен эленә торган пәрдә, палас һ. б.).

**ДРАПИРО'ВОЧНЫЙ** — пәрдәлек..., бүлмәне бизәүгә китә торган; *драпировочный материал* — пәрдәлек материал.

**ДРАПИРО'ВЩИК** *м.*, **ДРАПИРО'ВЩИЦА** *ж.* — драпировать итүче.

**ДРА'ПОВЫЙ** — драп ...; *драповое пальто* — драп пальто.

**ДРА'ТВА** *ж. мн.* нет, *сапожн.* — жеп очы (сумалалап ясалган жеп, сумалалы жеп).

**ДРАТЬ** *несов. разг.* — 1. (*рвать*) ерту, ерткалау; 2. (*изнашивать*) туздыру; 3. каезлау, төшерү, тунау; *драть лыко* — юкә каезлау, курыс төшерү; *драть шкуру* — тире тунау; 4. буу, ботарлау; *волк дерёт козу* — бүре кәҗәне буа; 5. чеметтерү, әчеттерү, яндыру; *перец дерёт горло* — борыч тамакны яндыра; 6. *неодобр.* (*дорого брать*) талау, тунау, тирене салдыру, тереләй тунау, кыйммәт бәягә сату; 7. качу, шылу, сызу; *драть во все лопатки* — җанфәрманга качу; 8. (*сечь*) яру, чыбыклау, суктыру, кыйнау, камчылау; 9. (*петь крикливо и фальшиво*) акыру, улау. ◇ **Драть горло (рот)** *просторечь.* — тамагын ерту, акыру. **Драть крупу** *спец.* — ярма ярдыру. **По коже дерёт** — тәнне чымырдата (салкыннан, куркудан). **Зубы драть** *просторечь.* — теш суыру. **Драть нос** *разг.* — борын күтәрү, борын чөю. **Уши драть** — колагын бору. **Бритва дерёт** — бритва авырттыра, бритва үтми. **Фуганок дерёт** — ышкы шома ышкыламый, ышкы үтми. **Сухая ложка рот дерёт** — коры кашык авыз ерта.

**ДРА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. сугышу, кыйнашу, якалашу; 2. *воен.* (*сражаться*) сугышу; 3. *перен. ритор.* көрәшү; *драться за выполнение плана* — планны үтәү өчен көрәшү; 4. *страд.* ертылу; туздырылу; каезлану, туналу.

**ДРА'ХМА** *ж.* — драхма (1. борынгы Грециядә көмеш яки алтын акча; 2. хәзерге Грециядә акча берәмлеге; 3. электә аптека үлчәве берәмлеге — 3,73 грамм).

**ДРАЧЛИ'ВЫЙ** — сугыш чукмары, сугышырга яратучан.

**ДРАЧУ'Н** *м.*, **ДРАЧУ'НЬЯ** *ж. разг.* — сугыш чукмары.

**ДРЕБЕДЕ'НЬ** *ж. мн.* нет, *разг. фам.* — чүп-чар, юк-бар нәрсәләр, вак-төякләр.

**ДРЕ'БЕЗГ:** 1. **с дребезгом** — чалтыратып; чалтырап, чылтыр итеп; 2. **в мелкие дребезги** — челпәрәмә; *разбить в мелкие дребезги* — челпәрәмә китерү; *разбиться в мелкие дребезги* — челпәрәмә килү.

**ДРЕБЕЗЖА'ТЬ** *несов.* — чылтырау, шылтырау.

**ДРЕВЕСИ'НА** *ж. мн.* нет — үзагач.

**ДРЕВЕ'СНИЦА** *ж.* — агач бакасы.

**ДРЕВЕ'СНЫЙ** — агач ...-ы; *древесный уголь* — агач күмере.

**ДРЕ'ВКО** *ср.* — сап, таяк; *древко флага* — флаг сабы (таягы).

**ДРЕВЛЕХРАНИ'ЛИЩЕ** *ср. офиц. устар.* — архив (борынгы әйберләр саклана торган урын).

**ДРЕ'ВНИЙ** — 1. борынгы; *древняя история* — борынгы тарих; 2. бик карт; *древний дуб* — бик карт имән.

**ДРЕ'ВНОСТЬ** *ж. книж.* — 1. (*давность*) борынгылык; 2. *только мн.* борынгы әйберләр; борынгы памятниклар. ◇ **В глубокой древности** — борын-борын заманда. **Седая древность** — борын заманнар.

**ДРЕ'ВО** *ср. устар.* — к. дерево.

**ДРЕВОВИ'ДНЫЙ** *книж.* — агачсыман, агач кебек.

**ДРЕВОЕ'Д** *м.* — агачашар (агач корты).

**ДРЕВОНАСАЖДЕ'НИЕ** *ср. книж.* — агач утырту.

**ДРЕВОТО'ЧЕЦ** *м. зоол.* — агач кисмәне (агач корты).

**ДРЕДНО'УТ** *м.* — дредноут (зур броненосец).

**ДРЕЗИ'НА** *ж. ж.-д.* — дрезина (тимер юл рельслары буенча мотор яки кул көче белән йөртелә торган кечкенә арба).

**ДРЕЙФ** *м. мор.* — дрейф (җил, су агымы тәэсире нәтиҗәсендә судноның бара торган юлыннан тайпылуы). ◇ **Лечь в дрейф** — дрейфка кую (җилкәнле корабльләрдә, җилкәннәрне төрлечә корып, корабльне хәрәкәтсез калдыру).

**ДРЕ'ЙФИТЬ** *несов. разг.* — шүрләү, куркып калу.

**ДРЕЙФОВА'ТЬ** *несов. мор.* — 1. тайпылу; 2. к. лечь в дрейф; 3. дрейфовать итү (үз ихтыяры белән хәрәкәт итәргә мөмкин булмау аркасында бер урында туктап тору яки йөзеп йөрү).

**ДРЕКО'ЛЬЕ** *ср. устар.* — күсәкләр, чукмарлар.

**ДРЕЛЬ** *ж. тех.* — дрель, борау, тишкеч.

**ДРЕМА'** *обл.*, **ДРЁМА** *ж. поэт. устар.* — к. дремота.

**ДРЕМА'ТЬ** *несов. просторечь.* — 1. йокымсырау, йокымсырап тору, калыгу, ою; 2. *перен.* селкенмәү, тып-тын (тору); *дремлет чуткий камыш* — сизгер камышлар тып-тын, селкенмиләр; 3. *перен. разг. фам.* мыштырдау; *пока ты дремал, он всё обделал в свою пользу* — син мыштырдаган арада, ул барысын да үз файдасына эшләп өлгергән; 4. *с отрицанием не* — уяу булу, сизгер булу.

**ДРЕМА'ТЬСЯ** *несов. безл. разг.* — йокы басу, йокымсырау; *мне дремлется* — мине йокы баса (йокым килеп тора).

**ДРЕМО'ТА** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. йокымсырау, йокымсырап тору; черем; 2. *перен. поэт.* тынлык, тынычлык.

**ДРЕМО'ТНЫЙ** *книж.* — 1. йокы аралаш; *дремотные мысли* — йокы аралаш уйлар; 2. *перен.* сүлпән, сүрән.

**ДРЕМУ'ЧИЙ** — кара, куе; *дремучий лес* — кара урман.

**ДРЕНА'Ж** *м.* — дренаж (1. *тех.* канаулар, трубалар ярдәмендә сазлыкны киптерү; 2. *мед.* шештәге яки ярадагы эренне көпшәләр ярдәмендә агызу).

**ДРЕНАЖИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. мед.*— эрен агызу.

**ДРЕНАЖИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. мед.*— эрен агызылу.

**ДРЕНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов., тех.*— корыту, киптерү (сазлыкларны).

**ДРЕНИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд., тех.*— корытылу, киптерелү.

**ДРЕСВА'** *ж. мн.* нет, *спец.*— эре ком, вак таш.

**ДРЕССИРОВА'ТЬ** *несов.*— өйрәтү, күнектерү (хайванны).

**ДРЕССИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— өйрәтелү, күнектерелү.

**ДРЕССИРО'ВЩИК** *м.*, **ДРЕССИРО'ВЩИЦА** *ж.*— хайван өйрәтүче; *дрессировщик собак* — этләр өйрәтүче.

**ДРОБИ'ЛКА** *ж. тех.*— ваткыч, ваклагыч (машина).

**ДРОБИ'ЛЬНЫЙ** I *тех.*— ваклый торган, ваклау ...-ы; *дробильная машина* — ваклый торган машина, ваклау машинасы.

**ДРОБИ'ЛЬНЫЙ** II *тех.*— к. дроболитейный.

**ДРОБИ'НА** *ж.*— бер бөртек ядрә.

**ДРОБИ'ТЬ** *несов.*— 1. (*измельчать*) ваклау; 2. *перен.* бүлгәләү, ваклау; *дробить вопрос* — мәсьәләне бүлгәләү.

**ДРОБИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. ваклану; 2. *перен.* бүлгәләнү, ваклану.

**ДРОБНИ'ЦА** *ж. охот.*— ядрә тартмасы, ядрә янчыгы.

**ДРО'БНО** *нареч.*— 1. вак итеп, ваклап; 2. тыпыр-тыпыр итеп, тыпырдап; *дробно стучали каблуки* — үкчәләр тыпыр-тыпыр итеп шакылдыйлар иде.

**ДРО'БНЫЙ** — 1. вакланган, бүлгәләнгән, вак; *дробный дождь* — вак яңгыр; 2. *мат.* вакланма ..., вакланмалы; *дробное число* — вакланма сан.

**ДРОБОВИ'К** *м. спец. разг.*— дробовик (ядрә белән ата торган мылтык).

**ДРОБОЛИТЕ'ЙНЫЙ** *тех.* — ядрә коя торган, ядрә кою ...-ы; *дроболитейный завод* — ядрә коя торган завод.

**ДРОБЬ** *ж.*— 1. (*для ружья*) ядрә; 2. *мат.* вакланма; *десятичная дробь* — унарлы вакланма; 3. *только ед.* ватык; *в стекле много дроби* — пыяла арасында ватыгы күп. ◇ **Соловей мелкой дробью рассыпался** — сандугач чут-чут итеп сайрый иде. **Барабанная дробь** — барабан тавышы.

**ДРОВА'** *ед. нет.*— утын. ◇ **Кто в лес, кто по дрова** — Гали үз эшендә, Вәли үз эшендә.

**ДРОВИ'ШКИ** *ед.* нет, *простореч.*— утын.

**ДРО'ВНИ** *ед.* нет — утын чанасы.

**ДРОВОЗАГОТО'ВКА** *ж.*— утын хәзерләү.

**ДРОВОКО'Л** *м.*— 1. утын яручы; 2. *обл.* утын балтасы, утын яра торган балта.

**ДРОВОКО'ЛЬНЫЙ** *тех.*— утын яру ...-ы, утын яра торган; *дровокольный станок* — утын яру станогы.

**ДРОВОРЕ'ЗНЫЙ** — утын кисү ...-ы, утын кисә торган; *дроворезный станок* — утын кисү станогы.

**ДРОВОСЕ'К** *м.*— 1. (*о человеке*) утын кисүче; 2. *зоол.* кисмән (бөҗәк).

**ДРОВЯНИ'К** *м.*— утынлык, утын сарае.

**ДРОВЯНО'Й** — 1. утын ...-ы; *дровяной склад* — утын склады; 2. утынга китә торган, утынлык ...; *дровяной лес* — утынлык (утынга китә торган) агачлар.

**ДРО'ГИ** *ед.* нет — 1. (*погребальная повозка*) мәет арбасы; 2. *обл.* (*крестьянские*) озын арба.

**ДРО'ГНУТЬ** I *несов.*— өшү, туңу.

**ДРО'ГНУТЬ** II *сов. книж.*— 1. селкенү, селкенеп китү; *дерево дрогнуло от удара топора* — балта белән суккач, агач селкенеп китте; 2. калтырап китү; *голос у него дрогнул* — тавышы калтырап китте; 3. хәрәкәткә килү; чигенә башлау; *толпа дрогнула* — халык хәрәкәткә килде; *неприятель дрогнул* — дошман чигенә башлады. ◇ **Рука не дрогнет** — кулы барыр, батырлыгы җитәр.

**ДРОЖА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — калтырау ...-ы; *дрожательные движения* — калтырау хәрәкәтләре.

**ДРОЖА'ТЬ** *несов.*— 1. селкенү, селкенеп тору; *пол дрожит от танцев* — биюдән идән селкенә; 2. калтырау, калтырану, дерелдәү, дер-дер итү, дер-дер килү; дерелдәп тору; *он дрожал от холода* — ул салкыннан калтырана иде; 3. леп-леп итеп тору, калтырау; *огонь в лампе дрожал* — лампа уты леп-леп итеп тора иде; 4. *книж.* калтырау, куркып тору; *мы не дрожали перед врагом* — дошман алдында без куркып тормадык; 5. борчылу, хафалану; *мать дрожала за своих детей* — ана балалары өчен борчыла иде. ◇ **Дрожит он над каждой копейкой** — бер тиен өчен җанын бирер, бик саран.

**ДРОЖЖЕВО'Й** — чүпрә ...-ы; *дрожжевой завод* — чүпрә заводы.

**ДРО'ЖЖИ** *ед.* нет — чүпрә.

**ДРОЖМЯ'**: **дрожмя дрожать** *разг. обл.*— бик нык калтырану, дер-дер килү.

**ДРОЖЬ** *ж. мн.* нет — калтырау, дерелдәү; калтырату; *его охватила дрожь* — ул калтырый башлады. ◇ **Дрожь пробежала у меня по спине** — аркам чымырдап китте. **Мелкая дрожь** — дер-дер килү. **Дрожь берёт (пробирает, пронимает)** — калтырата. **В дрожь бросает (кидает)** — калтырата.

**ДРОЗД** *м. зоол.*— миләш чыпчыгы.

**ДРО'ТИК** *м. истор.*— дротик, кыска саплы сөңге (борынгы сугыш коралы).

**ДРОФА', ДРОХВА'** *ж. зоол.*—дүдәк (дала кошы).

**ДРОЧЁНА** *ж. кулин.* — күпертмә (йомыркага сөт һәм он кушып хәзерләнгән ашамлык).

**ДРУГ** I *м.* (*мн. друзья*)— 1. дус, эшнә; *старый друг* — иске дус; *друг детей* — балалар дусты; 2. (*при обращении*) дускай, дустым; *вот такое дело, друг мой* — эшләр менә шулай, дускай. ◇ **Будь(те) другом** *разг.*— зинһар, зинһар өчен.

**ДРУГ** II: **друг друга** — бер-берсен; **друг другу** — бер-берсенә; **друг с другом** —

бер-берсе белән; **друг за другом** — бер-бер артлы; **друг над другом** — бер-берсеннән; **друг о друге** — бер-берсе турында; **они стоят друг друга** — алар пар килгән.

**ДРУГО'Й** — 1. бүтән, башка; *кто-то другой* — кемдер бүтән; *другой раз* — башка вакытта; 2. икенче; *на другой день* — икенче көнне; 3. *в знач. сущ.* — башка; *ему говоришь одно, а он делает совсем другое* — аңар бер нәрсә турында әйтәсең, ә ул бөтенләй башканы эшли; *заботиться о других* — башкалар турында кайгырту. ◇ **И тот и другой** — тегесе дә, монысы да; икесе дә, һәр икесе дә. **Это другое дело** *разг.* — алай булса, эш башка. **В другой раз** *простореч.* — кайчакта, кайвакытта. **Другими словами** *в знач. ввод. сл.* — икенче төрле әйткәндә, башкача әйткәндә.

**ДРУ'ЖБА** *ж. мн.* нет — дуслык; *в знак дружбы* — дуслык хөрмәтенә. ◇ **Не в службу, а в дружбу** — дуслык хөрмәтенә.

**ДРУЖЕЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — дуслык тойгысы, дуслык хисе.

**ДРУЖЕЛЮ'БНО** *нареч.* — дусларча, яратып; *нас встретили дружелюбно* — безне дусларча каршы алдылар.

**ДРУЖЕЛЮ'БНЫЙ** — дуслык ...-ы; дусларча ...; *дружелюбное отношение* — дуслык мөнәсәбәте; дусларча мөнәсәбәт.

**ДРУ'ЖЕСКИ** *нареч.* — дусларча; *дружески жму вашу руку* — кулыгызны дусларча кысам.

**ДРУ'ЖЕСКИЙ** — дуслык ...-ы, дусларча...; *дружеский привет* — дусларча сәлам. ◇ **Быть на дружеской ноге** — дусларча мөнәсәбәттә булу.

**ДРУ'ЖЕСТВЕННЫЙ** — 1. дуслык ...-ы; дусларча ...; *дружественный тон* — дуслык тоны; *дружественные отношения* — дусларча мөнәсәбәтләр; 2. дус ...; *дружественные нации* — дус милләтләр.

**ДРУ'ЖЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — к. дружба.

**ДРУЖИ'НА** *ж.* — 1. *истор.* дружина (борынгы Россиядә князьләр гаскәренең иң мөһим отряды); 2. дружина, группа, отряд.

**ДРУЖИ'ННИК** *м. истор.* — дружинник, дружина члены.

**ДРУЖИ'ТЬ** *несов.* — 1. дус булу, дус тору; 2. (*делать друзьями*) дусландыру, дуслаштыру, килештерү.

**ДРУЖИ'ТЬСЯ** *несов.* — дуслашу, дуслану.

**ДРУЖИ'ЩЕ** *м. разг.* — дускай.

**ДРУ'ЖКА** I *м. обл. истор.* — кияү егете.

**ДРУ'ЖКА** II *ж. обл.* — сынар, пар әйберенең берсе.

**ДРУ'ЖНИЙ** *устар.* — дусның, дус ...-ы; *дружнее счастье считать своим счастьем* — дусның бәхетен үз бәхетең итеп санау.

**ДРУ'ЖНО** *нареч.* — 1. дус, тату; *они жили очень дружно* — алар бик тату яшиләр иде; 2. бердәм, бердәм рәвештә, бергәләп, бергәләшеп, берьюлы; *они дружно взялись за работу* — алар эшкә бердәм керештеләр; 3. *разг.* тиз, бердәм; *снег стаял дружно* — кар тиз эреп бетте.

**ДРУ'ЖНЫЙ** — 1. дус, тату; *дружная семья* — тату семья; *быть дружным* — дус булу; 2. бердәм, берьюлы, бервакытта; *дружная работа* — бердәм эш; *колхозные поля покрылись дружными всходами озимых* — колхоз кырлары бердәм тишелеп чыккан уҗым белән капландылар. ◇ **В этом году весна была очень дружная** — быел яз бик тиз тотты (әйбәт килде).

**ДРУЖО'К** *м.* — дускай, иптәшкәй; *ты, дружок, очень хорошо сделал* — син, дускай, бик яхшы эшләгәнсең.

**ДРЫ'ГАТЬ** *несов. разг. фам.* — тыпырчыну.

**ДРЫ'ГАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — калтырау, калтырану, селкенеп-селкенеп китү.

**ДРЫ'ХАТЬ, ДРЫ'ХНУТЬ** *несов. простореч. неодобр.* — йокы симертү.

**ДРЯ'БЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — сәлперәйгәнлек, ләпшерәгәнлек, көпшәклек.

**ДРЯ'БЛЫЙ** — 1. сәлперәйгән, пәжегән; *дряблая кожа* — сәлперәйгән тире (тән); *дряблая репа* — пәжегән шалкан; 2. көпшәк; *дряблый камень* — көпшәк таш. ◇ **Человек с дряблым характером** — бик җебегән кеше.

**ДРЯ'БНУТЬ** *несов. разг.* — сәлперәю, пәжү.

**ДРЯЗГ** *м. мн.* нет, *обл.* — чүп, чүп-чар.

**ДРЯ'ЗГИ** *ед.* нет, *разг.* — төрле күңелсезлекләр, вак-төяк борчулар, вак-төяк ызгышлар.

**ДРЯ'ННО** *нареч. разг. фам. пренебр.* — начар, начар итеп.

**ДРЯННО'Й** *разг.* — начар.

**ДРЯНЬ** *ж. разг.* — 1. *только ед.* искемоскы, чүп-чар, алама-сәләмә; *он купил разной дряни* — һәртөрле иске-москы сатып алган; *он выбросил всю дрянь из стола* — өстәлдән бөтен чүп-чарны алып ташлады; 2. *только ед. пренебр.* түбән кеше; *такая дрянь, а ещё разговаривает* — шундый түбән кеше, сөйләшеп торган була тагын; 3. *в знач. сказ. разг. фам.* начар; *дело дрянь* — эш начар; *погода дрянь* — һава начар.

**ДРЯХЛЕ'ТЬ** *несов.* — какшау, бетерешү, мәлҗерәү, хәлсезләнү, таушалу (картаю сәбәпле).

**ДРЯ'ХЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — какшау, какшаганлык, хәлсезлек, картайганлык.

**ДРЯ'ХЛЫЙ** — 1. какшаган, хәлсезләнгән, таушалган, мәлҗерәгән; *дряхлый старик* — какшаган карт; 2. *перен.* искергән, искереп беткән; *дряхлые стены крепости рухнули от первого снаряда* — крепостьның искергән стеналары беренче снарядтан ук җимерелде.

**ДРЯХНУ'ТЬ** *несов. разг.* — к. дряхлеть.

**ДУАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — 1. *филос.* дуализм (монизмга капма-каршы буларак, дөньяның нигезендә бер-беренә бәйсез булган ике башлангыч, рух һәм материя ята дип раслый торган идеалистик тәгълимат); 2. *перен.* икелек, икегә аерылганлык.

**ДУАЛИ'СТ** *м. книж.* — дуалист, дуализм тарафдары.

**ДУАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *филос.*— дуалистик, дуализм ...-ы; *дуалистическое мировоззрение* — дөньяга дуалистик караш.

**ДУБ** *м.* имән. ◇ **Дуб-дубом** *бран.*— агач кебек; *стоит дуб-дубом и ничего не отвечает* — бер сүз дә дәшмичә, агач кебек катып тора.

**ДУБА'СИТЬ** *несов. простореч.*— 1. тукмау, дөмбәсләү, төю; 2. каты шакылдату, дөбердәтү, дыңгырдату; *дубасить в двери* — ишекләрне шакылдату.

**ДУБИ'ЛЬНЫЙ** — тире иләү ...-ы; тире иләүгә китә торган; *дубильный чан* — тире иләү чаны; *дубильные вещества* — тире иләүгә китә торган матдәләр.

**ДУБИ'ЛЬНЯ** *ж. мн.* нет — тире иләү бинасы.

**ДУБИ'ЛЬЩИК** *м.* — дубильщик, тире иләүче.

**ДУБИ'НА** — 1. *ж.* күсәк; 2. *м.* и *ж. разг.* ангыра, агач, күзле бүкән.

**ДУБИННОГОЛО'ВЫЙ** *разг.* — сантый, ангыра баш, аңгыра бәрәк, кибәк баш.

**ДУБИ'ТЕЛЬ** *м.*— иләгеч (тире иләгәндә кулланыла торган матдә).

**ДУБИ'ТЬ** *несов.*— тире иләү, иләү.

**ДУБИ'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— иләнү (тире).

**ДУБЛЁНКА** *ж. обл.*— тышсыз тун, кайры тун (иләп сарыга яки карага буялган тиредән тегелгән тун).

**ДУБЛЁНЫЙ** — 1. иләнгән; 2. иләнгән тиредән тегелгән.

**ДУБЛЁР** *м.*— дублёр (бер үк рольне башкаручы ике артистның берсе).

**ДУБЛЕ'Т** *м.*— дублет (1. бер төр әйбернең икенче данәсе; 2. ике көпшәле мылтыкның ике көпшәсеннән дә бер цельгә берьюлы атуы).

**ДУБЛЕ'ТНЫЙ** — икенче, дублет ...; *дублетный экземпляр* — икенче экземпляр.

**ДУБЛИКА'Т** *м. офиц.*— дубликат (документның төп документ хокукындагы күчермәсе).

**ДУБЛИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— 1. кабатлау (бер үк эшне ике җирдә эшләү); 2. копиясен, күчермәсен алу; *дублировать картину* — картинаның копиясен алу.

**ДУБЛИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— 1. кабатлану; 2. күчерелү, копиясе алыну.

**ДУБНЯ'К** *м. мн.* нет — имәнлек, имән урманы, туйралык.

**ДУБОВА'ТЫЙ** — тупасрак, аңгырарак, авыр гәүдәлерәк.

**ДУБОВИ'К** *м.*— имән гөмбәсе.

**ДУБО'ВЫЙ** — 1. имән ...-ы; *дубовый лист* — имән яфрагы; 2. имән ...; имәннән ясалган; *дубовый шкаф* — имән шкаф; 3. *разг. фам.* тупас, авыр; *у него язык дубовый* — аның теле авыр. ◇ **Дубовая голова** *простореч.*— аңгыра баш, сантый баш, кибәк баш.

**ДУБРА'ВА** *ж. поэт. устар. обл.*— имәнлек, туйралык.

**ДУБЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир. просторец.*— 1. күсәкләр, таяклар; 2. *бран.* ангыра сарыклар, аңгыра бәрәкләр, тинтәк кешеләр; *что с таким дубьём разговаривать!* — мондый аңгыра бәрәкләр белән нәрсә сөйләшеп торырга!

**ДУГА'** *ж.*— 1. дуга; 2. йөк; *подрядчик взял по рублю с дуги* — подрядчик йөк башыннан берәр сум алды. ◇ **Согнуть в дугу, согнуть в три дуги** *разг.*— мәҗбүр итү, бөгү, буйсындыру, күндерү.

**ДУГООБРА'ЗНЫЙ** *книж.*— дугасыман.

**ДУДЕ'ТЬ** *несов. разг.*— 1. сызгырту, сыбызгы сызгырту; 2. сызгыру.

**ДУ'ДКА** *ж.*— сыбызгы. ◇ **Плясать под дудку** — кубызына бию. **Рожь пошла в дудку** — арыш көпшәгә китте, арыш буынга сикерде, арыш тупсага утырды.

**ДУ'ДКИ** *межд. разг. фам.*— әләкми торсын! тәтеми торсын!

**ДУ'ЖКА** *ж.*— 1. дуга; 2. тотка; *ведёрная дужка* — чиләк тоткасы; 3. (*грудная кость у птиц*) ядәч сөяге.

**ДУКА'Т** *м. истор.*— дукат (Венециядә борынгы алтын акча).

**ДУ'ЛО** *ср.*— көпшә авызы; *дуло оружия* — мылтык көпшәсенең авызы.

**ДУ'ЛЯ** *ж. бот. обл.*— дуля (грушаның бер сорты).

**ДУ'МА** *ж.*— 1. *поэт. устар. обл.* (*мысль*) уй; 2. *полит. истор.* дума (элекке Россиядә вәкилләр җыелышы); *боярская дума* — боярлар думасы; *государственная дума* — дәүләт думасы.

**ДУ'МАТЬ** *несов.*— уйлау. ◇ **Много о себе думать** — үзен артык югары кую, үзен әллә кемгә санау. **Я думаю** *разг.*— әлбәттә, һичшиксез, үзеннән-үзе аңлашыла. **Не долго думая** *разг.*— озак уйламастан, озак уйлап тормыйча, шунда ук. **Думать думу** — уйга чуму.

**ДУ'МАТЬСЯ** *несов. безл. разг.*: **мне думается** — минемчә, минем фикеремчә; **нам думается** — безнеңчә, безнең фикеребезчә.

**ДУ'МЕЦ** *м. устар.*— дума члены, гласный.

**ДУ'МКА** *ж.*— 1. *обл.* уй; кечкенә генә уй; 2. *разг.* (*маленькая подушка*) колак мендәре, кечкенә мендәр.

**ДУ'ПЕЛЬ** *м.* (*мн. дупеля*) *зоол.*— урман үрдәге.

**ДУПЛИ'СТЫЙ** — куышлы, чокырлы; *дуплистый дуб* — куышлы имән; *дуплистый зуб* — чокырлы теш, тишекле теш.

**ДУПЛО'** *ср.*— 1. куыш (агачның үзәге черү сәбәпле уртасында барлыкка килгән бушлык); 2. *разг.* (*в зубе*) чокыр, тишек.

**ДУ'РА** *ж. разг.*— юләр, тиле, тинтәк, ахмак.

**ДУРА'К** *м. разг.*— юләр, тиле, тинтәк, ахмак. ◇ **Оставить в дураках** *перен. разг.*— кәкре каенга терәтү, төпсез чанага утырту. **Остаться в дураках** *перен. разг.*— уңайсыз хәлдә калу, төпсез чанага утыру. **Дурак дураком** *разг. фам.*— 1. шыр тиле; 2. тиле кеше кебек, бернәрсә аңламыйча. **Валять дурака** *просторец.*— 1. кылану; 2. ахмаклык эшләү. **Свалять дурака** — ахмаклык эшләп ташлау. **Круглый дурак** — шыр тиле. **На дурака** *просторец.*— ничек җитте алай.

**ДУРАКОВА'ТЫЙ** *разг.*— тилесыман, тиле-миле, аңгыра, юләрсымак.

**ДУРАЛЕ'Й** *м. разг.*— к. дурак.

**ДУРА'НДА** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — түп.

**ДУРА'ЦКИЙ** *разг.*: **дурацкий разговор**— мәгънәсез сүз; **дурацкие привычки** — юньсез (начар) гадәтләр; **дурацкие выходки** — тиләләрчә кыланышлар, юньсез кыланышлар.

**ДУРА'ЧЕСТВО** *ср. разг.*— юньсез кыланыш, шаяру; *брось свои дурачества!*— юньсез кыланышларыңны ташла!

**ДУРА'ЧИТЬ** *несов. разг.*— (тилегә санап) шаярту, алдау.

**ДУРА'ЧИТЬСЯ** *несов. разг.*— шаяру, юләрләнү.

**ДУРАЧО'К** *м.*— 1. *фам.* юләр; *прикидываться дурачком* — юләр булып кылану; 2. *простореч.* тиле, акылсыз, акылга зәгыйфь.

**ДУРАЧЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир. разг. фам.*— юләрләр, ахмаклар.

**ДУРА'ШЛИВЫЙ** *разг. фам.*— 1. юләрсымак, тилесымак; 2. *(шаловливый)* шаян, көлдерүчән, мәзәкчел.

**ДУ'РЕНЬ** *м. разг. фам.*— к. дурак.

**ДУРЕ'ТЬ** *несов. разг.*— ахмаклану, аңгыралану, тинтәкләнү.

**ДУРИ'ТЬ** *несов. разг.*— 1. шаяру, котыру, азу; *ребята, не дурите* — балалар, котырмагыз (шаярмагыз); 2. *(делать глупости)* ахмаклыклар эшләү; 3. *(упрямиться— о лошади)* чыгымлау, чыгымчылау.

**ДУРМА'Н** *м. мн.* нет — 1. *бот.* тиле бәрән орлыгы; 2. *перен. книж.* агу; *алкоголь — дурман* — алкоголь агу ул.

**ДУРМА'НИТЬ** *несов.*— 1. миңгерәүләндерү, исертү; *запах цветов дурманит голову* — чәчәкләр исе башны исертә; 2. *перен.* агулау, томалау; *религия дурманит сознание людей* — дин кешеләрнең аңын агулый.

**ДУРМА'НИТЬСЯ** *несов. страд.*— миңгерәүләндерелү.

**ДУРНЕ'ТЬ** *несов.*— ямьсезләнү, ямьсезләнә бару.

**ДУ'РНО** *нареч.*— начар; *дурно вести себя* — үзеңне начар тоту. ◇ **Почувствовать себя дурно** — баш әйләнү, хәл китү.

**ДУРНО'Й** — 1. начар, әшәке, яман; *дурная погода* — начар һава; *дурная слава* — яман ат; *дурной человек* — әшәке кеше; 2. *(некрасивый)* килбәтсез, ямьсез, шыксыз; 3. бозык, әдәпсез; *дурные привычки* — әдәпсез гадәтләр; 4. *обл. (глупый)* акылсыз, тилемсә, ахмак. ◇ **Дурной глаз** *разг.*— яман күз.

**ДУРНОТА'** *ж. мн.* нет — 1. баш әйләнү, күңел болгану; 2. *(о лице)* ямьсезлек.

**ДУ'РОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— ахмаклык, юләрлек; көйсезлек, холыксызлык.

**ДУРШЛА'Г** *м. кулин.*— дуршлаг, сөзгеч, тишекле чүмеч.

**ДУРЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— ахмаклык, юләрлек; дуамаллык; *выкинь дурь из головы!*— ташла бу ахмаклыгыңны!

**ДУ'ТИК** *м.*— 1. *(о предмете)* кечкенә куыш әйбер; 2. *разг. фам., дет. (о человеке)* үпкәчел, тиз үпкәләүчән.

**ДУ'ТЫЙ** — 1. өрдерелгән, өреп кабартылган; өреп ясалган; 2. *перен.* күпертелгән, арттырылган; ялган; *дутые цифры* — күпертелгән цифрлар; *дутая слава* — ялган дан.

**ДУТЬ** *несов.*— 1. исү, өрү; *ветер дует*— җил исә (өрә); 2. өрү; *дуть на горячий чай* — кайнар чәйгә өрү; 3. өреп ясау; *дуть бутылки* — өреп шешәләр ясау; 4. *простореч. (пить в большом количестве)* чүмерү; 5. *(делать быстро)* ...-а бирү, эшли бирү. ◇ **Он и в ус не дует** *разг.*— исе дә китми. **Дуть и в хвост, и в гриву** *простореч.*— ашыктыру, утлы табага бастыру.

**ДУ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— үпкәләү, турсаю, авыз турсайту.

**ДУХ** *м.*— 1. *только ед.* акыл, рух; *в здоровом теле здоровый дух* — сәламәт тәндә сәламәт акыл; 2. рух, дәрт; *дух войска* — гаскәрнең рухы; *поднять дух* — дәртне күтәрү; 3. *разг.* тын, сулыш; *у меня дух захватило* — сулышым кысылды, тыным кысылды; 4. *простореч.* һава; *из печки идёт тёплый дух* — мичтән җылы һава чыга; 5. *простореч.* ис; *из погреба идёт тяжёлый дух* — кар базыннан авыр ис чыга; 6. *миф.* җан, рух. ◇ **Быть не в духе** *разг.*— кәефсез булу, настроение начар булу. **Как на духу** *разг. устар.*— ачыктан-ачык, чын күңелдән. **Одним (единым) духом** *разг.*— берьюлы. **Во весь дух** *разг.*— бөтен көчкә, бөтен көч белән, җанфәрманга. **Дух вон** *простореч.*— үлде. **Вышибать дух** *простореч.*— кыйнап үтерү. **Испустить дух** *книж. устар.*— үлү, җан бирү. **Хватает духу** — батырлыгы җитә. **Ни слуху, ни духу** *разг.* — хәбәр-хәтер юк. **Присутствие духа** — батырлык, гайрәтлелек, йөрәклелек. **Собраться с духом** — гайрәтләнү, батырлану.

**ДУХИ'** *ед.* нет — ислемай, хушбуй.

**ДУХОВЕ'НСТВО** *ср. мн.* нет, *собир.*— руханилар, дин башлыклары.

**ДУХО'ВКА** *ж. разг.*— духовка (кухня плитасында).

**ДУХО'ВНЫЙ** — 1. рухи, мәгънәви; *духовные интересы* — рухи интереслар; 2. *церк.* духовный, дини, рухани; *духовная семинария* — духовный семинария; *духовные стихи* — дини шигырьләр; *духовное лицо* — рухани. ◇ **Духовное завещание** *офиц. устар.*— язма васыять.

**ДУХОВО'Й** — духовой, тынлы (өреп уйнала торган); *духовой оркестр* — духовой оркестр, тынлы оркестр.

**ДУ'ХОМ** *нареч. простореч.*— бик тиз генә, күз ачып йомганчы.

**ДУХОТА'** *ж. мн.* нет — 1. бөркүлек, тынчулык; 2. эсселек, кызулык.

**ДУШ** *м.*— душ (коену өчен ясалган җайланма).

**ДУША'** *ж.*— 1. *рел.* җан, рух; 2. күңел; *радостно на душе* — күңел шат; 3. *перен.* дәртләндерүче, рухландыручы, җанланды-

ручы; *он душа этого дела* — ул бу эшнең дәртләндерүчесе; 4. *разг.* кеше; *на улице ни души* — урамда бер генә кеше дә юк; *его семья состоит из пяти душ* — аның семьясы биш кешедән тора. ◇ **На душу населения** — кеше башына; җан башына. **По душе** — 1. күңелгә ошый; 2. *в знач. нареч.* яшермичә, чын күңелдән. **Отвести душу, излить душу** — әйтәсен әйтеп бетерү, күңелне бушату, эчне бушату. **От (всей) души** *разг.* — чын күңелдән. **Жить душа в душу** *разг.* — бик тату тору, дус тору. **Душа не лежит** *разг.* — күңел бармый, күңел тартмый. **Лежит на душе** *разг.* — күңелне борчып тора, йөрәктә төен булып тора. **Души не чаять** *разг.* — өзелеп ярату, үлеп ярату, бик нык ярату. **С души тянет (или воротит), душу мутит** *разг. фам.*—саруны кайната, косасыны китерә, җан биздергеч. **Душа не принимает** *разг.* — 1. туйдым, җитте; 2. җенем сөйми, күрәсем дә килми. **Вымотать (всю) душу** *разг.* — үзәгенә үтү, теңкәсенә тию. **Сколько душе угодно** — җаның теләгәнчә, җаның күпме тели. **Душой и телом** — җаны-тәне белән. **Душа на распашку** *разг.*— эчендәге тышында. **Душа в пятки ушла** *разг. шутл.* — коты чыкты, коты очты, җаны уч төбенә килде. **Душа с богом разговаривает** *разг. шутл. устар.*— очкылык тота. **По душам** *разг.* — чын күңелдән, ачыктан-ачык, дусларча. **Кривить душой**— ялганлау. **В чём душа держится** — җаны уч төбендә генә тора (бик арык, авыру кеше турында). **Ни душой, ни телом** *разг.*— һич тә, бөтенләй. **Брать на душу** — үз өстенә алу.

**ДУШЕ'ВНО** *нареч. разг.*— чын күңелдән, чын-чыннан; *душевно рад* — чын күңелдән шат.

**ДУШЕВНОБОЛЬНО'Й** *книж.* — психик авыру, акылына зыян килгән, акылы зәгыйфьләнгән.

**ДУШЕ'ВНЫЙ** — 1. күңел ... ы; *душевная тревога* — күңел тынычсызлыгы; 2. *(сердечный, искренний)* эчкерсез.

**ДУШЕГРЕ'ЙКА** *ж. устар.* — сырган камзол.

**ДУШЕГУ'Б** *м.* — җанкыйгыч, кеше үтерүче.

**ДУШЕГУ'БКА** I *ж.* — 1. *простореч.* к. душегуб; 2. *(узкая неустойчивая лодка)* әҗәл тагарагы.

**ДУШЕГУ'БКА** II *ж.* — душегубка (кешеләрне ябып газ белән тончыктырып үтерү өчен фашист илбасарлары тарафыннан кулланылган автомашина).

**ДУШЕГУ'БСТВО** *ср. простореч.* — кеше үтерү, җан кыю.

**ДУШЕПРИКА'ЗЧИК** *м.*, **ДУШЕПРИКА'ЗЧИЦА** *ж. юр.* — үлгән кешенең васыятьләрен үтәүче.

**ДУШЕРАЗДИРА'ЮЩИЙ** — коточкыч, җанәрнеткеч; *душераздирающий крик* — җанәрнеткеч тавыш.

**ДУШИ'СТЫЙ** — хуш исле.

**ДУШИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — буучы, кысучы, басучы, юл куймаучы; *фашизм — душитель свободы* — фашизм — азатлыкны буучы.

**ДУШИ'ТЬ** I *несов.* — 1. буу; 2. тын бетерү, тын кысу; *душит кашель* — ютәл тынны бетерә; 3. буу, кысу, басу, юл куймау; *душить свободу* — ирекне кысу.

**ДУШИ'ТЬ** II *несов.* — ислемай сөртү, ислемай сибү, хушбуй сөртү, хушбуй сибү.

**ДУШИ'ТЬСЯ** I *несов. страд.* — буылу, томалану, кысылу.

**ДУШИ'ТЬСЯ** II *несов.* — ислемай сөртенү, хушбуй сөртенү.

**ДУШИ'ЦА** *ж. бот.* — мәтрүшкә.

**ДУ'ШКА** — 1. *м.* и *ж. разг. фам.* сөйкемле кеше; 2. *ж. простореч. (ямка на шее)* муен чокыры; 3. *ж. (у птиц)* ядәч сөяге.

**ДУ'ШНО** *безл. в знач. сказ.* — 1. бөркү, тынчу; *в комнате душно* — бүлмәдә бөркү; 2. тын бетә, сулыш тарая; *мне душно* — минем тыным бетә, минем сулышым тарая.

**ДУ'ШНЫЙ** — бөркү, тынчу, авыр һавалы, эссе.

**ДУШО'К** *м. мн.* нет, *разг.* — ис; *мясо с душком* — исләнә башлаган ит; *газета с либеральным душком* — газетадан либераллык исе аңкып тора.

**ДУЭ'ЛЬ** *ж. устар.* — дуэль (дворян-буржуаз җәмгыятьтә берсенең чакыруы буенча ике кеше арасында барган атышу яки кылыч белән сугышу).

**ДУЭ'Т** *м. муз.*— дуэт (1. ике музыка коралында бергә уйнау өчен яки ике тавыштан җырлау өчен язылган музыкаль әсәр; 2. ике тавыштан җырлау яки ике музыка коралында бергә уйнау).

**ДЫБИ'ТЬСЯ** *несов., книж. редко* — үрә тору (ат турында).

**ДЫ'БОМ** *нареч.* — тырпаеп. ◇ **Волосы дыбом (встали)** *перен.* — чәчләре үрә торды.

**ДЫБЫ'**: **на дыбы** — 1. *(о лошадях)* үрә тору; 2. *перен. разг.* аяк терәп каршы тору.

**ДЫ'ЛДА** *м.* и *ж. простореч. бран.* — колга, телеграм баганасы (килбәтсез, озын буйлы кеше турында).

**ДЫМ** *м.* — 1. *только ед.* төтен; 2. *истор.* морҗа, өй; *раньше платили дань с дыма* — элекке заманда ясакны морҗа башыннан түләгәннәр. ◇ **Дым коромыслом** — шау-шу, тәртипсезлек. **Нет дыма без огня** — утсыз төтен чыкмый, җилсез кура селкенми.

**ДЫМА'РЬ** *м. с.-х.* — төтәткеч, төтенләгеч (умартачылыкта).

**ДЫМИ'ТЬ** *несов.* — 1. төтенләү, төтен чыгару, төтен кайтару; *печь дымит* — мич төтен кайтара; 2. төтәү, төтенләтү, төтен чыгару; *дымить папиросой* — папирос тартып төтен чыгару.

**ДЫМИ'ТЬСЯ** *несов.* — төтен чыгу, төтен кайту, төтенләү. ◇ **Туман дымился над рекой** — елга өстендә томан күтәрелгән иде, томан җәелеп тора иде.

**ДЫ'МКА** *ж. мн.* нет — 1. сыек томан; 2. җиңел (юка) материя; 3. *перен.* томанлы сурәт, томанлы күренеш.

**ДЫ'МНЫЙ** — төтенле; *дымная головешка* — төтенле кисәү; *дымный порох* — төтенле дары.

**ДЫМОВО'Й** — 1. төтен ...-ы; *дымовая труба* — төтен трубасы; 2. төтен үткәрми торган; *дымовая маска* — төтен үткәрми торган маска.

**ДЫМО'ВЬЕ** *ср. обл.* — өй, кара өй.

**ДЫМОХО'Д** *м.* — юллык, төтен юлы (мичтә).

**ДЫ'МЧАТЫЙ** — соргылт, төтенсыман.

**ДЫ'ННЫЙ** — кавын ...-ы; *дынное семечко* — кавын орлыгы.

**ДЫ'НЯ** *ж.* — кавын.

**ДЫРА'** *ж.* — 1. тишек, ертык; 2. *только мн.* житешсезлекләр.

**ДЫРОКО'Л** *м. разг.* — кәгазь тишкеч.

**ДЫ'РЧАТЫЙ** *обл.* — тишекле, тишек-тишек.

**ДЫРЯ'ВИТЬ** *несов. простореч.* — тишү.

**ДЫРЯ'ВЫЙ** — тишек; *дырявый мешок* — тишек капчык. ◇ **Дырявая голова, дырявая память** *разг.* — онытучан, тавык мие эчкән.

**ДЫХА'НИЕ** *ср.* — 1. *(вздох)* сулыш, сулыш алу, тын алу; *последнее дыхание* — соңгы сулыш; 2. *(веяние)* сулыш, аңкыш; *дыхание весны* — яз сулышы. ◇ **Не переводя дыхания** — сулыш алмастан, тынын да алмыйча, бертуктаусыз.

**ДЫХА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — сулыш алу ...-ы; тын алу ...-ы; *дыхательные органы* — тын алу органнары.

**ДЫХНУ'ТЬ** *однокр.* — бер кат сулыш алу, өреп карау; *дыхни-ка на меня!* — өреп кара әле миңа!

**ДЫША'ТЬ** *несов.* — тын алу, сулау, сулыш алу. ◇ **Уж небо осенью дышало** — инде күктә көз якынлашканы сизелеп тора иде. **Его лицо дышало молодостью** — аның йөзеннән яшьлек аңкып тора иде. ◇ **Дышать на ладан** или **еле дышать** *разг.* — кабер якасында тору.

**ДЫША'ТЬСЯ** *безл.*: **легко дышится** — сулыш алырга җиңел; **тяжело дышится** — тын кысыла, сулыш тарая.

**ДЫ'ШЛО** *ср.* — дышло (бер тәртәле арбаның тәртәсе).

**ДЬЯ'ВОЛ** *м. миф.* — шайтан, иблис. ◇ **Какого дьявола или за каким дьяволом?** *разг. вульг.* — ни шайтаныма? ни өчен? ник?

**ДЬЯВОЛЁНОК** *м. разг. перен.* — шук бала, шаян бала.

**ДЬЯ'ВОЛЬСКИ** *нареч. разг. фам.* — бик, бик нык; *я дьявольски устал* — мин бик нык арлым.

**ДЬЯ'ВОЛЬСКИЙ** — 1. иблис ...-ы, шайтан ...-ы; *дьявольское наваждение* — иблис вәсвәсәсе, шайтан котыртуы; 2. *разг.* явыз ниятле, мәкерле; *дьявольский умысел* — мәкерле ният (уй); 3. *разг.* — коточкыч, бик авыр; *дьявольская работа* — бик авыр эш.

**ДЬЯ'ВОЛЬЩИНА** *ж. мн.* нет, *разг.* — буталчыклык, аңлашылмау.

**ДЬЯК** *м. истор.* — дьяк (борынгы Россиядә берәр дәүләт учреждениесендә секретарь эшен алып баручы).

**ДЮ'ЖЕ** *нареч. обл.* — бик, бик каты.

**ДЮ'ЖИЙ** *простореч.* — көчле, зур гәүдәле, эре сөякле.

**ДЮ'ЖИНА** *ж* — дюжина, унике данә. ◇ **Чёртова дюжина** *шутл.* — унөч.

**ДЮ'ЖИННЫЙ** — гади, уртача.

**ДЮЙМ** *м. устар.* — дюйм (электә озынлык үлчәве берәмлеге — 23 миллиметр чамасы).

**ДЮЙМО'ВЫЙ** — бер дюймлы, бер дюйм озынлыгындагы; *дюймовый гвоздь* — бер дюймлы кадак.

**ДЮ'НЫ** *мн.* — дюналар (җил өюдән ясалган ком калкулыклары).

**ДЮРАЛЮМИ'НИЙ** *м. хим. тех.* — дюралюминий (самолётлар ясауда кулланыла торган җиңел һәм бик ныклы эретмә).

**ДЮШЕ'С** *м. бот.* — дюшес (груша сорты).

**ДЯ'ДЕНЬКА** *м.* — к. дядя.

**ДЯ'ДИН** абыйның, абый ...-ы, абыйныкы; *дядин дом* — абый өе.

**ДЯ'ДЬКА** *м. разг.* — 1. *пренебр. дет.* абый; 2. *истор. (слуга)* дядька (электә дворян малайларын караучы хезмәтче).

**ДЯ'ДЮШКА** *м. разг.* — абзыкай, абзый.

**ДЯ'ДЯ** *м.* (*мн.* дядья) — 1. абый, абзый (атаның яки ананың ир туганы); 2. (*обращение к взрослому мужчине*) — абый, абзый.

**ДЯ'ТЕЛ** *м. зоол.* — тукран.

**ДЯ'ТЛОВЫЙ** — тукран ...-ы; *дятловое гнездо* — тукран оясы.

# Е

**Е'ВА** *ж. миф.* — хаува, хаува ана.

**ЕВА'НГЕЛИЕ** *ср. рел.* — инҗил (христианнарның дини китабы).

**ЕВГЕ'НИКА** *ж. мн.* нет — евгеника (биологик юл белән „кешеләр токымын яхшыртып була" дип раслый торган үтә реакцион буржуаз тәгълимат).

**Е'ВНУХ** *м. устар.* — евнух, хәрәм агасы.

**ЕВРЕ'И** *мн.* — еврейләр, еврей халкы.

**ЕВРЕ'Й** *м.* — еврей.

**ЕВРЕ'ЙКА** *ж.* — еврей хатын-кызы.

**ЕВРОПЕ'ЕЦ** *м.* — европалы, Европа кешесе.

**ЕВРОПЕИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — европалашу; европалаштыру.

**ЕВРОПЕИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — европалаштыру.

**ЕВРОПЕИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. европалашу; 2. *страд.* европалаштырылу.

**ЕВРОПЕ'ЙСКИЙ** — Европа ...-ы; *европейский континент* — Европа континенты.

**ЕВРОПЕ'ЙЦЫ** *мн.* — европалылар, Европа халыклары.

**Е'ГЕРЬ** *м.* (*мн.* éгери, егеря́) — 1. *устар.* профессиональ аучы; 2. *дореволь.* егерь (кайбер армияләрдә укчы-егерь полкында хезмәт итүче солдат).

**ЕГИПТО'ЛОГ** *м. книж.* — египтолог (борынгы Египетны өйрәнүче белгеч).

**ЕГИПТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — египтология (борынгы Египетны өйрәнү).

**ЕГИПТЯ'НЕ** *мн.* — египетлылар, Египет халкы.

**ЕГИПТЯ'НИН** *м.* — египетлы.

**ЕГИПТЯ'НКА** *ж.* — египетлы хатын-кыз.

**ЕГОЗА'** *м. и ж. разг.* — кыбырсык, тиктормас.

**ЕГОЗИ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. кыбырсыклану, тик тормау; 2. *неодобр.* — (*угодничать*) ялагайлану, куштанлану.

**ЕДА'** *ж. мн.* нет — 1. (*пища*) ашамлык, азык; 2. ашау; аш; *перед едой* — аш (ашау) алдыннан; *после еды* — аштан соң; ашаганнан соң.

**ЕДВА'** — 1. *нареч.* — көчкә, көчкә генә, көчкә-көчкә; *он едва дошёл до больницы* — ул больницага көчкә генә килеп җитте; 2. *нареч.* чак кына, чак-чак, аз гына; *едва жив* — аз гына җаны бар; *комната едва освещалась маленькой лампочкой* — кечкенә лампа бүлмәне чак кына яктырта иде; 3. *союз* белән үк, ...-гач та; *он едва вошёл, как начал говорить* — керү белән үк (кергәч тә) сөйли башлады. ◇ **Едва-едва** — чак-чак. **Едва ли** — ай-һай ...-мы икән; белмим ...-мы икән; *едва ли он придёт скоро* — ай-һай, ул тиз килерме икән. **Едва ли не...** — диярлек; *умел говорить едва ли не на всех языках* — барлык телләрдә диярлек сөйләшә белә иде. **Едва не...** — ...-а язды(м,н); *едва не упал* — егыла язды (м, н).

**ЕДИНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — берләшү, бердәмлек; *единение масс в борьбе за мир* — тынычлык өчен көрәштә массаларның бердәмлеге.

**ЕДИНИ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — берләштерү.

**ЕДИНИ'ЦА** *ж.* — 1. (*цифра*) бер, берлек; 2. (*школьная отметка*) берле, берле билгесе; 3. *только мн. мат.* (*последняя цифра многозначных чисел*) берәмлекләр; 4. *книж.* берәмлек; *единицей измерения силы тока служит ампер* — токның көчен үлчәү берәмлеге — ампер; 5. *книж.* берәмлек; *хозяйственная единица* — хуҗалык берәмлеге (тәрҗемә итәргә мөмкин булмаса, әйбернең исеме әйтелә, мәсәлән, *эскадра состояла из десяти боевых единиц* — эскадра ун сугыш корабленнән тора иде); 6. *книж.* (*отдельное лицо*) шәхес, аерым кеше; 7. *только мн. книж.* аерым кешеләр, кайберәүләр; *на собрание не пришли только единицы* — җыелышка аерым кешеләр генә килмәде.

**ЕДИНИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — бер генә булу, бердәнберлек, сирәклек; *единичность факта* — фактның бер генә булуы.

**ЕДИНИ'ЧНЫЙ** *книж.* — 1. (*при сущ. в ед. ч.*) бер генә, бердәнбер, аерым; *единичный факт* — бердәнбер факт; 2. (*при сущ. во мн. ч.*) — аерым, сирәк очрый торган; *единичные случаи* — аерым очраклар.

**ЕДИНОБО'РСТВО** *ср. книж.* — бергә-бер сугышу (көрәш); кара-каршы сугышу (көрәш); *единоборство охотника с леопардом* — аучының каплан белән бергә-бер сугышуы.

**ЕДИНОБО'РСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — бергә-бер көрәшү, кара-каршы сугышу.

**ЕДИНОБРА'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — моногамия (бер генә хатынлылык, бер генә ирлелек).

**ЕДИНОВЛА'СТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — власть бер кулда булу, ялгыз властьлылык.

**ЕДИНОВЛА'СТНО** *нареч.* — бер ялгызы гына; *единовластно управлять* — бер ялгызы гына идарә итү.

**ЕДИНОВЛА'СТНЫЙ** *книж.* — ялгыз властьлы (бер үзе власть башында торучы).

**ЕДИНОВРЕ'МЕННО** *нареч.* — берьюлы, бер генә вакытта.

**ЕДИНОВРЕ'МЕННЫЙ** — 1. берьюлы ...-а торган, бердән ...-а торган; бер тапкыр (мәртәбә) ...-а торган; *единовременная помощь* — бер тапкыр бирелә торган ярдәм; 2. *книж.* (*одновременный*) бер вакытта гына ...-а торган.

**ЕДИНОГЛА'СИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — бердәмлек, бер фикердә булу.

**ЕДИНОГЛА'СНО** *нареч.* — бертавыштан, бер авыздан; *резолюция была принята единогласно* — резолюция бертавыштан кабул ителде.

**ЕДИНОГЛА'СНЫЙ** *книж.* — 1. бер авыздан ...-ган, бертавыштан ...-ган; *единогласное решение* — бертавыштан кабул ителгән карар; 2. бердәм; *единогласное мнение собрания* — җыелышның бердәм фикере.

**ЕДИНОДУ'ШИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — бердәмлек, бердәм булу, бер фикердә булу; *единодушие народов в борьбе за мир* — тынычлык өчен көрәштә халыкларның бердәмлеге.

**ЕДИНОДУ'ШНО** *нареч.* — 1. к. единогласно; 2. бердәм булып, бердәм рәвештә; *сотни миллионов людей единодушно присоединяются к требованиям борцов за мир* — йөз миллионнарча кешеләр тынычлык өчен көрәшүчеләрнең таләпләренә бердәм рәвештә кушылалар.

**ЕДИНОДУ'ШНЫЙ** — 1. бердәм; *единодушное желание* — бердәм теләк; *единодушная подписка на заём* — заёмга бердәм язылу; 2. бер авыздан; *единодушное признание* — бер авыздан тану (икърар итү).

**ЕДИ'НОЖДЫ** *нареч. устар. книж.* — бер җирдә, бер тапкыр; *единожды пять — пять* — бер җирдә бишең — биш.

**ЕДИНОКРО'ВНЫЙ** *книж.* — 1. ата бер, ана башка; 2. токымдаш, нәселдәш, бер токымнан, бер нәселдән.

**ЕДИНОЛИ'ЧНИК** *м.*— аерым хуҗалыкчы.

**ЕДИНОЛИ'ЧНО** *нареч.*— бер үзе, бер генә кеше, үзе генә; *нельзя единолично решать такой вопрос* — мондый мәсьәләне бер генә кешегә хәл итәргә ярамый.

**ЕДИНОЛИ'ЧНЫЙ** — **1.** аерым; *единоличное хозяйство* — аерым хуҗалык; **2.** үзе генә, бер ялгызы, ялгыз, бер генә кеше ...-а торган; *единоличное решение вопроса* — мәсьәләне бер үзе (бер ялгызы) хәл итү; *единоличная ответственность* — ялгыз җаваплылык; *единоличная власть* — бер генә кеше идарә итә торган власть.

**ЕДИНОМЫ'СЛИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— бер фикердә булу, бер фикерлелек, фикердәшлек.

**ЕДИНОМЫ'ШЛЕННИК** *м. книж.*— **1.** фикердәш; **2.** *(сообщник)* сердәш, катнашучы (сердә яки эшерен эштә).

**ЕДИНОМЫ'ШЛЕННЫЙ** — фикердәш, бер фикерле, бер фикердә булган, бер карашлы.

**ЕДИНОНАСЛЕ'ДИЕ** *ср. мн.* нет, *юр. истор.* — бер варислылык (мирасның олы улга гына күчүе).

**ЕДИНОНАЧА'ЛИЕ** *ср. мн.* нет — бер үзе идарә итү.

**ЕДИНОНАЧА'ЛЬНИК** *м. офиц.* — единоначальник; ялгыз идарә итүче.

**ЕДИНООБРА'ЗИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — бертөслелек, бертөрлелек, беррәвешлелек.

**ЕДИНООБРА'ЗНЫЙ** *книж.* — бертөсле, бертөрле.

**ЕДИНОПЛЕМЕ'ННИК** *м.*, **ЕДИНОПЛЕМЕ'ННИЦА** *ж. книж.*— милләттәш, кабиләдәш.

**ЕДИНОПЛЕМЕ'ННЫЙ** *книж.* — кабиләдәш.

**ЕДИНОУТРО'БНЫЙ** *книж.* — **1.** *юр.* ана бер, ата башка; *единоутробный брат* — ана бер, ата башка ага (яки эне); **2.** *устар.* бертуган.

**ЕДИ'НСТВЕННО** *нареч. книж.*— **1.** бердәнбер; *единственно возможный способ* — бердәнбер мөмкин булган ысул; **2.** *(только)* тик, бары тик, фәкать; *мы обязаны единственно ему* — без бары тик аңар гына бурычлы. ◇ **Всё единственно** *простореч. фам.*— барыбер.

**ЕДИ'НСТВЕННЫЙ** — **1.** бердәнбер; *единственный ребёнок* — бердәнбер бала; **2.** *перен. (исключительный)* искиткеч, дөньяда бер; *единственная красота* — дөньяда бер матурлык. ◇ **Единственный в своем роде** — дөньяда бер (кеше, әйбер, күренеш). **Единственное число** *грам.*— берлек саны.

**ЕДИ'НСТВО** *ср.*— **1.** гомумилек; *единство интересов* — интересларның гомумилеге; **2.** бердәмлек; *единство партии* — партиянең бердәмлеге; *морально-политическое единство советского народа* — совет халкының мораль-политик бердәмлеге; **3.** үзара бәйләнеш, бердәмлек; *единство теории и практики* — теория һәм практиканың үзара бәйләнеше (бердәмлеге).

**ЕДИ'НЫЙ** *книж.*— **1.** бердәм, берләштерелгән; *единый план* — бердәм план; *единое командование* — берләштерелгән (бердәм) командование; **2.** бердәм; *единый народный фронт* — бердәм халык фронты; **3.** бер; *единое целое* — бер бөтен; *ни единой минуты* — бер генә минут та; *он не возражал ни единым словом* — ул бер генә сүз белән дә каршы килмәде; **4.** *(единственный)* бердәнбер. ◇ **Все до единого** — бөтенесе дә, һәммәсе дә, барысы да, берсе дә калмыйча. **Всё едино** *простореч. фам.*— барыбер.

**Е'ДКИЙ** — **1.** зәһәр, зәһәрле; ашый, кисә, яндыра торган; *едкая кислота* — зәһәр (кисә, яндыра, ашый торган) кислота; **2.** ачы; *едкий дым* — ачы төтен; *едкий запах* — ачы ис; **3.** *перен.* ачы, әрнетүле, әрнеткеч, чәнчүле; *едкая насмешка* — ачы көлү (чәнчүле сүзләр әйтеп көлү).

**Е'ДКОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** зәһәрлелек, ашаучанлык (кислота турында); **2.** ачылык; *едкость дыма* — төтеннең ачылыгы; **3.** *перен. разг.* ачы сүз, ачы көлү, чәнчүле сүз.

**ЕДО'К** *м.*— **1.** кеше башы; *распределить по едокам* — кеше башыннан бүлү; **2.** *обл.* ашаучы, тамак, кашык (семьяда); *в семье три едока* — семьяда өч тамак; **3.** *разг.* күп ашаучы, туймас тамак.

**ЁЖ** *м. зоол.*— керпе.

**[ЕЖЕ]** — ...саен, ...саен була торган; *ежедневно* — көн саен.

**ЕЖЕВЕЧЕ'РНИЙ** — һәр кич була торган.

**ЕЖЕВИ'КА** *ж. мн.* нет, *бот.*— кара бөрлегән.

**ЕЖЕВИ'ЧНИК** *м. обл.*— кара бөрлегәнлек.

**ЕЖЕВИ'ЧНЫЙ** — кара бөрлегән ...-ы; *ежевичный куст* — кара бөрлегән куагы.

**ЕЖЕГО'ДНИК** *м. книж.*— еллык, елга бер тапкыр чыга торган (мәсәлән, журнал).

**ЕЖЕГО'ДНО** *нареч. книж.*— һәр елны, ел саен.

**ЕЖЕГО'ДНЫЙ** *книж.*— һәр ел була торган, ел саен була торган; *ежегодная ревизия* — ел саен була торган ревизия.

**ЕЖЕДНЕ'ВНО** *нареч.*— көн саен, һәр көнне.

**ЕЖЕДНЕ'ВНЫЙ** — **1.** һәр көн ...-а торган, көн саен ...-а торган; *ежедневная газета* — көн саен чыга торган газета; **2.** көндәлек; *ежедневные заботы* — көндәлек кайгыртулар, көндәлек мәшәкатьләр.

**Е'ЖЕЛИ** *союз устар. простореч.*— к. если.

**ЕЖЕМЕ'СЯЧНИК** *м. книж.* — айлык, айга бер чыга торган (газета, журнал).

**ЕЖЕМЕ'СЯЧНО** *нареч.*— ай саен, һәр айда; *журнал выходит ежемесячно* — журнал ай саен чыга.

**ЕЖЕМЕ'СЯЧНЫЙ** — һәр айда ...-а торган, ай саен ...-а торган; *ежемесячный журнал* — ай саен чыга торган журнал.

**ЕЖЕМИНУ'ТНО** *нареч.*— минут саен, һәр минутта.

**ЕЖЕМИНУ'ТНЫЙ** — минут саен ...-а торган; һәр минутта ...-а торган.

**ЕЖЕНЕДЕ'ЛЬНИК** *м. книж.*— атна саен чыга торган, атнага бер чыга торган (газета, журнал).

**ЕЖЕНЕДЕ'ЛЬНО** *нареч. книж.*— атна саен; *стенная газета выпускается еженедельно* — стена газетасы атна саен чыгарыла.

**ЕЖЕНЕДЕ'ЛЬНЫЙ** *книж.*— атна саен ...-а торган, атнага бер ...-а торган.

**ЕЖЕНО'ЩНЫЙ** *книж. устар.*— һәр төнне ...-а торган.

**ЕЖЕСЕКУ'НДНО** *нареч.*— секунд саен, һәр секундта.

**ЕЖЕСЕКУ'НДНЫЙ** — секунд саен ...-а торган, һәр секундта ...-а торган.

**ЕЖЕЧА'СНО** *нареч.*— сәгать саен, һәр сәгатьтә.

**ЕЖЕЧА'СНЫЙ** — сәгать саен ...-а торган, һәр сәгатьтә ...-а торган.

**ЁЖИК** *м. разг.*— к. ёж.

**ЁЖИТЬСЯ** *несов.*— **1.** бөрешү, куырылу (суыктан); **2.** *перен. разг.* тартыну, оялу.

**ЕЖО'ВЫЙ** — керпе ... -ы; *ежовая нора* — керпе оясы. ◇ **Держать в ежовых рукавицах** *разг.*— каты тоту.

**ЕЗДА'** *ж. мн.* нет — **1.** к. ездить и ехать; **2.** юл, юлда булу; *в трёх часах езды от города* — шәһәрдән өч сәгатьлек юл; *долгая езда утомительна* — озак юл ардыра.

**Е'ЗДИТЬ** *несов.*— йөрү, барып йөрү (атланып, утырып).

**Е'ЗДКА** *ж. просторен.*— бару; *кубометр дров можно привезти в одну ездку* — бер кубометр утынны бер баруда китерергә була.

**ЕЗДОВО'Й** — **1.** җигелә торган, җигеп йөри торган; *ездовая лошадь* — җигеп йөри торган ат; **2.** *воен. в знач. сущ.* кучер, ездовой (артиллериядә).

**ЕЗДО'К** *м.*— **1.** җайдак, атлы; *устар.* юлаучы; **2.** йөри белүче; *отличный ездок на велосипеде* — велосипедта яхшы йөри белүче. ◇ **Не ездок** *разг.*— бармаячак(мын, сын), килмәячәк(мен, сен).

**ЕЗЖА'ТЬ** *многокр.* — баргалау; *езжали мы туда частенько* — анда без еш баргалый (торган) идек.

**Е'ЗЖЕНЫЙ** — **1.** йөрергә өйрәтелгән; *езженая лошадь* — йөрергә өйрәтелгән ат; **2.** *(о дороге)* йөрелгән, тапталган, такыр; *езженая дорога* — йөрелгән юл. ◇ **Езжено-переезжено** *просторен.*— күп йөрелде, күп йөрергә туры килде.

**ЁКАТЬ** *несов. разг.*— йөрәк кагу (ат турында). ◇ **Сердце ёкает** — йөрәгем сикерә, йөрәгем леп-леп тибә (куркудан яки дулкынланудан).

**ЁКНУТЬ** *однокр.*— дерт итеп китү; *сердце ёкнуло* — йөрәгем дерт итеп китте.

**Е'ЛЕ, Е'ЛЕ-Е'ЛЕ** *нареч.*— көчкә генә, көчкә-көчкә генә, чак кына, чак-чак кына, көч-хәл белән генә. ◇ **Еле-еле душа в теле** — җаны чыгарга тора, җаны уч төбендә генә (кеше турында); таралырга тора (ватык әйбер турында).

**ЕЛЕ'Й** *м. мн.* нет — **1.** *церк.* зәйтүн мае (чиркәүдә гыйбадәт кылганда кулланалар); **2.** *перен. поэт.* тынычлагыч, рәхәт биргеч.

**ЕЛЕ'ИНОСТЬ** *ж. мн.* нет — юмакайлык, төче теллелек, ялагайлык.

**ЕЛЕ'ЙНЫЙ** — **1.** зәйтүн мае ...-ы; *елейный дым* — зәйтүн мае төтене; **2.** *перен. неодобр.* ялагай, юмакай; *елейный голос* — ялагай тавыш; *елейное выражение лица* — юмакай чырай.

**ЕЛИ'КО** *нареч.*: **елико возможно** *разг. устар.*— мөмкин кадәр, мөмкин булганча, кулдан килгәнчә.

**ЁЛКА** *ж. разг.*— **1.** к. ель; **2.** ёлка (яңа елга каршы үткәрелә торган балалар бәйрәме).

**ЕЛО'ВЫЙ** — **1.** чыршы ...-ы; *еловая шишка* — чыршы күркәсе; **2.** чыршы ..., кара чыршы ..., чыршыдан ясалган; *еловая доска* — чыршы такта.

**ЕЛО'ЗИТЬ** *несов. просторен.*— әрле-бирле үрмәләп йөрү, әрле-бирле шуышып йөрү; *елозить по полу* — идән буенча әрле-бирле үрмәләп йөрү.

**ЁЛОЧНЫЙ** — ёлка ...-ы; *ёлочные украшения* — ёлка бизәгечләре.

**ЕЛЬ** *ж. бот.*— чыршы, кара чыршы.

**Е'ЛЬНИК** *м.*— **1.** *(еловый лес)* чыршылык, кара чыршы урманы; **2.** *(ветви ели)* чыршы ботаклары (киселгәннәре).

**ЁМКИЙ** — сыемлы, күп сыйдырышлы.

**ЁМКОСТЬ** *ж. мн.* нет — сыем, сыйдырыш, сыешлык; сыйдыра алу дәрәҗәсе. ◇ **Ёмкость рынка** — базарның товар үткәрә алу мөмкинлеге. **Меры ёмкости** — сыек һәм бөртекле әйберләрнең күләмен үлчәү берәмлекләре.

**ЕНО'Т** *м.*— **1.** *(пушной зверь)* янут; **2.** *(мех)* янут мехы; **3.** *только мн.* янут мехыннан тегелгән киемнәр.

**ЕНО'ТОВЫЙ** — янут ...; янут мехыннан тегелгән; *енотовый воротник* — янут яка; *енотовая шуба* — янут мехыннан тегелгән тун.

**ЕПАНЧА'** *ж. истор.*— япанча (борынгы заманда киң озын плащ).

**ЕПИ'СКОП** *м. церк.*— епископ (православие чиркәвендә югары дәрәҗәле рухани).

**ЕРАЛА'Ш** *м. мн.* нет, *разг. фам.*— тәртипсезлек, буталчыклык.

**ЕРЕПЕ'НИТЬСЯ** *несов. просторен.*— киреләнү, кәҗәләнү, тискәреләнү, каршы килү, үҗәтләнү.

**Е'РЕСЬ** *ж.*— **1.** *рел.* ересь (хөкем сөрә торган диннең кагыйдәләренә каршы килә торган дини тәгълимат); **2.** (бәхәссез дип саналган карашлардан һәм кагыйдәләрдән) читкә китү, тайпылу; **3.** *перен.* сафсата, юк-бар сүз, төпсез фикер, буш сүз.

**ЕРЕТИ'К** *м. церк.*— еретик (ересь яклы кеше).

**ЁРЗАТЬ** *несов. разг.*— тик утырмау, кыбырсыклану, боргалану.

**ЕРМО'ЛКА** *ж.*— ермолка (түбәтәйсыман баш киеме).

**ЕРО'ШИТЬ** *несов. разг.* — тырпайту, чуалту, тузгыту (чәчне).

**ЕРО'ШИТЬСЯ** *несов. разг.*— тырпаю, тырпаеп тору.

**ЕРУНДА'** *ж. мн.* нет, *разг. фам.*— **1.** *(вздор, чепуха)* сафсата, буш сүз, юк-

бар сүз, мәгънәсез сүз, әһәмиятсез сүз; әһәмиятсез нәрсә; 2. җиңел; *научиться плавать — сущая ерунда* — йөзәргә өйрәнү — бик җиңел.

**ЕРУНДИ'ТЬ** *несов. простореч.*— 1. *(говорить ерунду)* юк-барны сөйләү; 2. *(делать ерунду)* кирәкмәгән эш эшләү.

**ЁРШ** I *м.*— 1. *(рыба)* шыртлака, ертыш; 2. *тех.* тешле кадак (кире чыкмасын өчен); 3. щётка (мәсәлән, лампа куыгын чистарта торган щётка).

**ЁРШ** II *м. мн.* нет, *разг.*— аракы катыш сыра.

**ЕРШИ'СТЫЙ** *разг.*— 1. *(о волосах)* тырпайган; 2. *перен. (неуступчивый)* кире, үҗәт, кире беткән, үз сүзле.

**ЕРШИ'ТЬ** *несов.*— 1. *простореч.* к. ерошить; 2. теш ясау, сырлау (кадакны, суырып алынмасын өчен).

**ЕРШИ'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— киреләнү, үҗәтләнү, үз сүзлеләнү, кәҗәләнү.

**ЕРШО'ВЫЙ** — шыртлака балык ...-ы; *ершовая уха* — шыртлака балык шулпасы.

**ЕСАУ'Л** *м. дореввол.* — есаул (казачи частьларда офицер чины).

**Е'СЛИ** *союз* — 1. *(с глаголом наст. или буд. вр.)* әгәр ...-са, әгәр дә ... -са, ...-са; *если придёт, пусть зайдёт ко мне* — әгәр (әгәр дә) килсә, минә керсен; 2. *(с инфинитивом)* әгәр ...-саң, әгәр дә ...-саң, ...-саң; *если растение не поливать, то оно засохнет* — әгәр (әгәр дә) үсемлеккә су сипмәсәң, ул корыр; 3. *(в знач.: в то время, как)* ... -ган вакытта, ...-са; *если неимущие страдали от недоедания, то богатые болели от переедания* — ярлылар ачлы-туклы торудан җәфа чиксә, байлар күп ашаудан авыруга сабышалар иде; 4. ...-а алганны, ...-ганны; *если уж ты сделал, то он и подавно сделает* — син эшли алганны (эшләгәнне) ул күптән эшли алыр. ◇ **Если бы, если б** — 1. *(в начале придат. предложения)* әгәр дә ...-са, әгәр дә ...-ган булса; *если б он мог...* — әгәр дә аның мөмкинлеге булса; 2. *(в начале восклицательн. предлож.)* эх ...-са иде,эх ...-ган булса иде; *если бы он знал!* — эх, ул белгән булса иде! ... **если (и) не ..., то** — булмаса да, ...-маса; *эта мебель, если и не изящна, то удобна* — бу мебель, матур эшләнгән булмаса да, уңайлы; *это сделает если не один, то другой* — моны берсе эшләмәсә, икенчесе эшләр.

**ЕСТЕ'СТВЕННИК** *м.*, **ЕСТЕ'СТВЕННИЦА** *ж. разг.*— табигатьче, табигать белгече.

**ЕСТЕ'СТВЕННО** — 1. *нареч.* табигый рәвештә, табигый; 2. *ввод. сл.* билгеле, әлбәттә.

**ЕСТЕ'СТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — табигыйлек.

**ЕСТЕ'СТВЕННЫЙ** — 1. табигый, табигать ...-ы; *естественные богатства Татарии* — Татарстанның табигый байлыклары; *естественные науки* — табигать фәннәре; 2. *(непринуждённый, простой)* гади, табигый. ◇ **Естественное дело** *разг.*— әлбәттә, билгеле.

**ЕСТЕСТВО'** *ср. мн.* нет — 1. төп, асыл, үз; *естество вопроса* — мәсьәләнең асылы; 2. *устар.* табигать.

**ЕСТЕСТВОВЕ'Д** *м. книж.*— табигатьче, табигать белгече.

**ЕСТЕСТВОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— табигать белеме.

**ЕСТЕСТВОЗНА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— табигать фәннәре.

**ЕСТЕСТВОИСПЫТА'ТЕЛЬ** *м. книж.*— табигать фәннәре белгече.

**ЕСТЬ** I — 1. ул; *что есть истина?* — хакыйкать нәрсә ул? 2. *(имеется)* бар; *есть надежда* — өмет бар. ◇ **Есть такое дело!** *простореч. фам.*— ярый, эшләрмен, син дигәнчә булыр. **Что есть сил** — җан фәрманга, бөтен көчкә. **Так и есть** — чынлап та. **Как есть** *разг.*— бөтенләй. **Что есть, то есть** — бары бар инде, аны танып булмый. **Какой ни есть (или ни на есть)** — нинди генә булса да. **То есть** — ягъни.

**ЕСТЬ** II *несов.*— 1. *(принимать пищу)* ашау; 2. ашау, ую, кисү; *кислота ест ткани* — кислота тукыманы кисә; *ржавчина ест железо* — тутык тимерне ашый; 3. *перен.* әчеттерү; *дым ест глаза* — төтен күзне әчеттерә; 4. *перен. (бранить)* талау, чәйнәү, җанны ашау. ◇ **Есть поедом кого-либо** *разг.*— көн бирмәү, көн күрсәтмәү. **Ест глазами** — күзе белән ашый (күзләрне текәп карау турында).

**ЕФРЕ'ЙТОР** *м. воен.*— ефрейтор (армиядә солдаттан югары беренче звание).

**Е'ХАТЬ** *несов.*— 1. бару; *ехать верхом на лошади* — атка атланып бару; *ехать на санях* — чанада бару; 2. китү; *мы едем в экспедицию* — без экспедициягә китәбез; *завтра еду в Москву* — иртәгә Москвага китәм; 3. *перен. разг.* шуышу, таю; *ноги на льду едут в разные стороны* — боз өстендә аяклар төрле якка тая; *галстук едет набок* — галстук читкә шуыша. ◇ **Дальше ехать некуда** — актык чиккә җиткән инде, моннан соң ни әйтәсең инде.

**ЕХИ'ДА** *ж. простореч.*— к. ехидна 2.

**ЕХИ'ДНА** *ж.*— 1. *зоол.* ехидна (а. Австралиядә яши торган керпесыман хайван; б. Австралиядә яши торган агулы елан); 2. *перен. простореч. бран.* мәкерле кеше, усал кеше, кара елан, кара эчле.

**ЕХИ'ДНИЧАТЬ** *несов. разг.*— мыскыллау, мыскыллап көлү, чәнчү, чәнчүле сүзләр әйтү.

**ЕХИ'ДНЫЙ** *разг.*— 1. мәкерле, хәйләкәр, хәйләле; *ехидный человек* — мәкерле (хәйләле) кеше; 2. ачы, чәнчүле, зәһәр; *ехидный смех* — ачы көлү.

**ЕХИ'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.*— ачы теллелек; мәкерлелек, хәйләкәрлелек.

**ЕЩЁ** *нареч.*— 1. тагы, тагын, янә; *возьми ещё эту книгу* — тагы бу китапны ал; 2. әле; *нет ещё* — юк әле; *он ещё не окончил школу* — ул әле мәктәпне бетермәгән; 3. инде, ук; *он уехал ещё неделю тому назад* — ул инде моннан бер атна элек китте; *он приехал из армии ещё в прошлом году* — армиядән ул узган елда ук кайтты; 4. тагын да; *он ещё сильнее* — ул

тагын да көчлерәк; **5.** *разг. (в знач. усил. частицы)* гына, ... әле, тагын; *как ещё получится!* — ничек кенә килеп чыгар әле! *какой ещё подарок ему!* — нинди бүләк тагын аңар! **6.** *разг. (в знач. ввод. сл.)* җитмәсә тагы үзе; *почему ты не был на собрании? — ещё комсомолец!* — нигә син җыелышта булмадың? — җитмәсә тагы үзең комсомолец! ◇ **Ещё бы** *разг.* — әлбәттә, билгеле. **Всё ещё** — әле хәзер дә, һаман, хәзергә кадәр. **Ещё ничего** *разг.* — ярый әле, ярыйсы әле. **А ещё...** *разг. фам.* — җитмәсә тагы. **Ещё и ещё** — тагын да күбрәк. **Нет ещё** — әлегә юк.

# Ж

**Ж** *союз* — к. же I.

**ЖА'БА** I *ж. зоол.* — гөберле бака җир бакасы, сасы бака, йорт бакасы.

**ЖА'БА** II *ж. мед. устар.* — к. ангина.

**ЖА'БЕРНЫЙ** *зоол.* — **1.** саңаклы; *жаберные животные* — саңаклы хайваннар; **2.** саңак ...-ы; *жаберные дужки* — саңак дугалары; **3.** саңак белән ... ; *жаберное дыхание* — саңак белән сулау.

**ЖА'БНИК** *м. бот.* — куян йоны (сары чәчәкле купьеллык үлән).

**ЖАБРЕ'Й** *м. бот.* — күзлут (чүп үлән).

**ЖА'БРЫ** *мн.* — саңак (балык, кысла кебек су хайваннарының сулыш алу органнары). ◇ **Взять за жабры** *простореч. вульг.* — бугазыннан алу, эләктерү.

**ЖА'ВОРОНОК** *м. зоол.* — тургай, сабан тургае.

**ЖА'ДИНА** *м.* и *ж., разг. фам.* — комсыз, ачкүз; карун.

**ЖАДНЕ'ТЬ** *несов., разг.* — комсызлана бару; саранлана бару.

**ЖА'ДНИЧАТЬ** *несов., разг. фам.* — **1.** *(желать захватить возможно больше)* комсызлану; ач күзлеләнү; **2.** *(скупиться)* саранлану, карунлану, саранлык күрсәтү.

**ЖА'ДНО** *нареч.* — **1.** комсызланып, ач күзләнеп, туймастай булып; **2.** *перен.* ашкынып, атлыгып, йотлыгып, дәртләнеп, чын күңелдән бирелеп; *жадно слушать* — йотлыгып тыңлау.

**ЖА'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** *(алчность)* комсызлык; ач күзлелек; **2.** *разг. (скупость)* саранлык, хиреслек, карунлык. ◇ **С жадностью** *перен.* — йотлыгып, бирелеп; *он с жадностью слушал музыку* — ул йотлыгып музыка тыңлый иде.

**ЖА'ДНЫЙ** — **1.** *(алчный)* комсыз; **2.** *разг.* саран, карун, хирес; *жадный человек* — саран кеше; **3.** *перен.* атлыгып торучы, ашкынып торучы; *познанья жадный* — белем алуга ашкынып тора. ◇ **С жадным вниманием** — бик зур игътибар белән, йотлыгып. **С жадным любопытством** — тирән кызыксыну белән.

**ЖА'ЖДА** *ж. мн.* нет — **1.** сусау, сусын, эчәсе килү; *утолить жажду* — сусауны басу; **2.** *перен. книж. (стремление, желание)* көчле теләк, ашкыну, атлыгу.

**ЖА'ЖДАТЬ** *несов. книж.* — **1.** сусау, эчәсе килү, тамак кибү; **2.** *перен. (страстно желать)* көчле рәвештә теләү, нык теләү, ашкынып тору.

**ЖАЛЕ'ТЬ** *несов.* — **1.** *(испытывать жалость)* кызгану, аяу, җәлләү; **2.** үкенү; *он жалеет о допущенной ошибке* — ул җибәргән хатасы өчен үкенә; **3.** кызгану; *жалеть деньги* — акча кызгану.

**ЖА'ЛИТЬ** *несов.* — чагу; *пчёлы жалят* — умарта кортлары чага.

**ЖА'ЛКИЙ** — **1.** кызганыч, аяныч; *иметь жалкий вид* — кызганыч кыяфәттә булу; *старик был жалок* — карт кызганыч иде; **2.** мескен, боек, бичара; *жалкая улыбка* — мескен (боек) елмаю; **3.** начар, бик начар; *рукопись имела жалкий вид* — кульязма бик начар иде; **4.** бик аз, бик кечкенә; *жалкая сумма* — бик аз акча. ◇ **Жалкие потуги стать писателем** — юкка гына язучы булырга маташу. **Жалкая смерть** — даныксыз үлем. **Жалкие слова** — кызгандыргыч сүзләр. **Жалкие подхалимы** — җирәнгеч ялагайлар. **Жалкая роль** — түбән роль.

**ЖА'ЛКО** *нареч.* — кызганыч, аяныч.

**ЖА'ЛО** *ср.* — **1.** *(у насекомых)* ук, чаккыч; **2.** *(у крапивы)* чәнечке, чаккыч; **3.** *(у удочки)* тел; **4.** *(остриё чего-н.)* оч; **5.** *перен. поэт.* ук; *жало сатиры* — сатира угы.

**ЖА'ЛОБА** *ж.* — **1.** *(выражение неудовольствия)* зар, зарлану; **2.** *офиц.* жалоба; *подать жалобу* — жалоба бирү.

**ЖА'ЛОБНО** *нареч.* — ялынып, ялварып; моңаеп, нәүмизләнеп.

**ЖА'ЛОБНЫЙ** — **1.** кызганыч, җан әрнеткеч; **2.** *офиц.* жалобалар ...-ы; *жалобная книга* — жалобалар кенәгәсе.

**ЖА'ЛОБЩИК** *м.*, **ЖА'ЛОБЩИЦА** *ж. юр.* — жалоба бирүче.

**ЖА'ЛОВАННЫЙ** *устар.* — бүләк ителгән, бүләк итеп бирелгән. ◇ **Жалованная грамота** *истор.* — льготалар грамотасы (льготалар белән файдалану өчен югары власть тарафыннан бирелгән грамота).

**ЖА'ЛОВАНЬЕ** *ср. устар.* — жалованье, хезмәт хакы, эш хакы.

**ЖА'ЛОВАТЬ** *несов. устар.* — **1.** *(награждать)* бүләкләү, бүләк итү, бүләк итеп бирү; **2.** *устар. ирон.* килү; *ко мне он жалует частенько* — ул миңа еш кына килә; **3.** *преимущ. с отриц.* тәкъдир итү, ярату; *его не очень жалуют* — аны бик үк яратып бетермиләр.

**ЖА'ЛОВАТЬСЯ** I *несов.* — **1.** зарлану; *жаловаться на боль* — авыртудан зарлану; **2.** *(подавать жалобу)* жалоба бирү; **3.** *разг. (ябедничать)* әләкләү, чагу.

**ЖА'ЛОВАТЬСЯ** II *несов. страд.*— 1. бүләк ителү, бүләк итеп бирелү; 2. тәкъдир ителү, яратылу.

**ЖАЛОНО'СНЫЙ** *зоол.* — уклы, чаккычлы, чага торган.

**ЖА'ЛОСТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — кызганучанлык, мәрхәмәтлелек, йомшак күңеллелек, жәлләүчәнлек.

**ЖА'ЛОСТЛИВЫЙ** *разг.* — кызганучан, йомшак күңелле, жәлләүчән, мәрхәмәтле.

**ЖА'ЛОСТНЫЙ** — 1. к. жалостливый; 2.сагышлы, кызганыч, аяныч, жан әрнеткеч; *жалостная песня* — сагышлы җыр; *жалостный вид* — аяныч кыяфәт.

**ЖА'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. кызгану, жәлләү; шәфкать; 2. кайгы, үкенеч.

**ЖАЛЬ** — 1. *в знач. сказ.* кызгану, жәлләү; жәл; *мне жаль тебя* — мин сине жәллим; 2. *в знач. ввод. сл., разг.* кызганычка каршы, үкенечкә каршы.

**ЖАНДА'РМ** *м. дореврл.*— жандарм.

**ЖАНДАРМЕ'РИЯ** *ж. мн.* нет, *дореврл. собир.*— жандармерия (патша Россиясендә һәм кайбер капиталистик илләрдә революцион хәрәкәткә каршы көрәшү өчен оештырылган полиция гаскәре).

**ЖАНР** *м.* — 1. жанр (а. нинди дә булса сәнгать әсәрләренең үзенә генә хас булган сюжет билгеләре һәм стилистик билгеләр белән аерылып тора торган бер төре; б. көнкүрешне сурәтли торган сынлы сәнгать); 2. *перен. разг.* стиль, манера.

**ЖАНРИ'СТ** *м.* — жанрист (көнкүрешне сурәтләүче художник).

**ЖАР** *м. мн.* нет — 1. *(зной)* кызулык, эсселек; 2. *разг.* кызу, эссе; *мы выехали в самый жар* — көн кызуында (көннең иң кызу вакытында) чыгып киттек; 3. *разг. (жаркое место)* эссе урын, кызу урын; 4. *разг. (горячие угли)* утлы күмер; 5. *перен.* дәрт, ашкыну; *работать с жаром* — дәртләнеп эшләү. ◇ **Больной в жару** — авыру кызыша. **Задать жару** *разг. фам.*— кыздыру, кирәген бирү, утлы табага бастыру. **Как жар горит** — ялт итеп тора; ут кебек янып тора. **Поддать жару** — 1. *разг.* пар җибәрү (мунчада кызган таш өстенә су салу); 2. *перен. разг. фам.* дәртләндерү, дәртләндереп җибәрү. **Чужими руками жар загребать** *погов. неодобр.*— кеше кулы белән ут көрәү.

**ЖАРА'** *ж. мн.* нет— эссе, кызу; эсселек, кызулык; *в комнате была сильная жара* — бүлмәдә бик эссе иде.

**ЖАРГО'Н** *м.*— жаргон (аерым бер социаль группа кешеләре арасында гына кулланыла торган һәм үзенең грамматик төзелеше, төп сүзлек фонды булмаган „сыйнфый" диалектлар).

**ЖАРДИНЬЕ'РКА** *ж.*— жардиньерка, гөл савыты.

**ЖА'РЕНОЕ** *ср. мн.* нет, *разг.* — к. жаркое.

**ЖА'РЕНЫЙ** — кыздырылган, куырылган.

**ЖА'РИТЬ** *несов.* — 1. кыздыру, кыздырып пешерү; *жарить котлеты* — котлет кыздыру; 2. куыру; киптерү; *горох жарить* — борчак куыру; 3. пешерү, кыздыру; *солнце жарит* — кояш пешерә; 4. *простореч.* күп ягу, кыздыру; *нельзя так жарить печь* — мичне болай кыздырырга ярамый. ◇ **Жарить на гармонике** *простореч. фам.*— гармоньда әйттерү. **Жарь в аптеку!** *простореч. фам.*— элдерт аптекага! Йөгер аптекага! **Так и жарит книгу за книгой** *простореч. фам.* — китап артыннан китапны укып кына тора.

**ЖА'РИТЬСЯ** *несов.*— 1. *страд.* куырылу; кыздырылу; 2. *разг.* кызыну; *жариться на солнце* — кояшта кызыну.

**ЖА'РКИЙ** — 1. *(знойный)* кызу, эссе; 2. кайнар; *жаркая печь* — кайнар мич; *жаркие слёзы* — кайнар яшьләр; 3. *перен.* кызу; *жаркий спор* — кызу бәхәс.

**ЖА'РКО** — 1. *нареч.* эссе итеп, кызу итеп; 2. *нареч. перен.* кызып, кызу рәвештә; *жарко спорить* — кызып бәхәсләшү; 3. *в знач. сказ.* эссе, кызу; *в июле в Ташкенте очень жарко* — июльдә Ташкентта бик эссе була. ◇ **Так, что небу жарко станет** *разг. фам.* — җәһәннәм тишегендә дә урын таба алмассың.

**ЖАРКО'Е** *ср.*— куырдак, жаркой (кыздырып пешерелгән ит).

**ЖАРО'ВНЯ** *ж.*— тимер учак.

**ЖАРОВО'Й** — 1. эссе һава йөри торган; *жаровая труба* — эссе һава йөри торган труба; 2. күмер белән кыздырыла торган; *жаровой утюг* — күмер белән кыздырыла торган үтүк; 3. эссе; *жаровой удар* — эссе сугу.

**ЖАРОПОНИЖА'ЮЩИЙ** *мед.*— эсселекне киметә торган, температураны төшерә торган.

**ЖАРОУСТО'ЙЧИВЫЙ** — кызуга чыдам.

**ЖАР-ПТИ'ЦА** *ж.*— бәхет кошы (әкиятләрдә сөйләнә торган алтын каурыйлы кош).

**ЖАСМИ'Н** *м. мн.* нет, *бот.*— ясмин (куак агач).

**ЖАСМИ'ННЫЙ, ЖАСМИ'НОВЫЙ** — ясмин ...-ы; *жасминный запах* — ясмин исе.

**ЖА'ТВА** *ж. мн.* нет — 1. *(действие)* уру; 2. *(время уборки хлебов)* урак өсте; 3. *книжн.*— өлгергән иген, ашлыклар; 4. *перен. книжн.* табыш, төшем, уңыш.

**ЖА'ТВЕННЫЙ** *с.-х.* — уру ...-ы; *жатвенные машины* — уру машиналары.

**ЖА'ТКА** *ж. с.-х.* — уру машинасы, ургыч.

**ЖАТЬ** I *несов.*— 1. кысу; *жать руку* — кулны кысу; *сапог жмёт ногу* — итек аякны кыса; 2. сыгу, кысып чыгару; *жать сок из винограда* — виноградның согын сыгу; 3. *перен. разг. (угнетать)* кысу, изү. ◇ **Жать соки** — җелеген суыру.

**ЖАТЬ** II *несов.*— уру.

**ЖА'ТЬСЯ** I *несов.*— 1. *(тесниться)* кысылу; 2. сырышу, елышу, сыену; *ребёнок жался к матери* — бала анасына сырыша иде; 3. *перен. разг. (мяться, стесняться)*

тартыну, оялып тору; 4. *перен. (скупиться)* саранлану, кысылу.

**ЖА'ТЬСЯ** II *несов. страд.*— урылу.

**ЖБАН** *м. обл.*— ыжбан, су савыты.

**ЖВА'ЧКА** *ж. мн.* нет — күшәм; күшәү. ◇ **Жевать жвачку — 1.** күшәү; **2.** *перен. ирон.* бер балык башын чәйнәү, сеңер чәйнәү. **Кормить ребёнка жвачкой** — балага имезлек бирү.

**ЖВА'ЧНЫЙ** — күшәүче, күши торган.

**ЖГУТ** *м.*— жгут (каештан, баудан, саламнан каты итеп ишелгән яки үрелгән кыска бау).

**ЖГУ'ЧИЙ** — 1. кайнар, эссе, кызу; *жгучие лучи солнца* — кояшның кайнар нурлары; *жгучий воздух* — эссе һава; 2. чатнаган, чеметтереп ала торган; *жгучий мороз* — чатнаган (чеметтереп ала торган) суык; 3. *перен.* чыдамаслык, бик каты, йөрәккә тиярлек; *жгучая боль* — чыдамаслык авырту; 4. *перен.* кайнар; *жгучие слёзы* — кайнар күз яшьләре; 5. *перен.* ачы, чәнечкеле, үткен; *жгучая насмешка* — ачы көлү. ◇ **Жгучий брюнет** — чем-кара күзле, чем-кара чәчле кеше. **Жгучий вопрос** — бик мөһим (бик әһәмиятле) мәсьәлә (бөтен халыкны кызыксындыра торган мәсьәлә).

**ЖДАТЬ** *несов.*— 1. *(ожидать)* көтү, көтеп тору; 2. өмет итү, көтеп тору; *враг не может ждать пощады* — дошман рәхимшәфкать өмет итә алмый; *каждый день жди какой-н. новости* — һәр көнне нинди дә булса берәр яңалык көт тә тор; 3. уйлау,... дип уйлау, ышанып тору; *ждали, что он будет хорошим работником* — ул яхшы работник булыр дип уйлаганнар иде. ◇ **Того и жди** *разг.*— көт тә тор. **Ждать не дождаться** *разг.*— көтә-көтә көтек булу (көтеп ала алмау). **Ждать у моря погоды** — аяз көктән яңгыр көтү.

**ЖЕ** I *союз* — 1. *(противительный)* ә, исә; *сами пошли в театр, меня же оставили дома* — үзләре театрга киттеләр, ә мине өйдә калдырдылар; 2. *(присоединительный)* ә; *когда мы приехали, приехали же мы летом, стояла солнечная погода* — без килгән чакта, ә без җәен килгән идек, көннәр кояшлы иде. ◇ **Всё же** — шулай да, шулай булса да, шуңа карамастан.

**ЖЕ** II *частица* — 1. *(усилительная)* соң, инде, бит, ук; *когда же вы будете готовы?* — кайчан соң сез әзер булырсыз? *пойдём же!* — барыйк инде! *говорите же!* — сөйләгез инде! *мы поедем сегодня же* — без бүген ук китәрбез; *есть же у нас хорошие книги!* — бездә яхшы китаплар бар бит; 2. *(для указания тожества)* ук, үк; *тот же* — шул ук; *такой же* — шундый ук; *здесь же* — биредә үк.

**ЖЁВАНЫЙ** *разг.* — 1. чәйнәлгән; 2. *перен. фам.* изелгән, бөгәрләнеп беткән.

**ЖЕВА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *анат.* чәйнәү ...-ы; *жевательные мышцы* — чәйнәү мускуллары; 2. чәйни торган; *жевательная резина* — чәйни торган резина.

**ЖЕВА'ТЬ** *несов.*— 1. чәйнәү; 2. *простореч. фам.* ашау. ◇ **Жевать жвачку** — 1. күшәү; 2. *перен. ирон. неодобр.* бер балык башын чәйнәү.

**ЖЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— чәйнәлү.

**ЖЕЗЛ** I *м.* — 1. *истор.* жезл (түрәлек һәм дәрәҗә билгесе булган махсус таяк); 2. *устар. (палка, посох)* таяк.

**ЖЕЗЛ** II *м.*— жезл (1. тимер юлда поездларның йөрешен тәртипкә салу өчен хезмәт итә торган автомат приборның металл таягы; 2. *геод.* җир өстен төгәл үлчәү приборы).

**ЖЕЛА'НИЕ** *ср.*— теләк, дәрт; *иметь желание* — теләк булу; *гореть желанием* — дәрт белән яну. ◇ **При всём моём желании** — никадәр генә теләсәм дә.

**ЖЕЛА'ННЫЙ** — 1. көтелгән, көтеп алынган, теләп алынган; 2. *устар.* сөекле, газиз, кадерле; *желанный друг* — кадерле дус.

**ЖЕЛА'ТЕЛЬНО** — 1. кирәк, яхшы булыр, мәслихәт; *деньги желательно получить до отъезда* — акчаны киткәнче алу яхшы булыр; 2. теләү, ...-сы килү; *мне желательно знать* — минем беләсем килә.

**ЖЕЛА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — кирәклек, мәслихәтлек.

**ЖЕЛА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. офиц.* — кирәкле, көтелгән, теләгән; *дело приняло желательный для нас оборот* — эш без теләгән юнәлешне алды. ◇ **Желательное наклонение** *лингв.*— теләк фигыль.

**ЖЕЛАТИ'Н** *м. мн.* нет, *хим.* — желатин, җилем (хайван сөягеннән һәм тиресеннән ясала торган җилем).

**ЖЕЛАТИ'ННЫЙ, ЖЕЛАТИ'НОВЫЙ** — 1. желатинлы; *желатинная бумага* — желатинлы кәгазь; 2. желатин..., желатиннан ясалган; *желатиновые пластинки* — желатин пластинкалар.

**ЖЕЛА'ТЬ** *несов.* — теләү. ◇ **Оставляет желать многого (или лучшего)** — канәгатьләнерлек түгел. **Какого (какой, каких) только можно желать** — иң яхшы, моннан да яхшысы булмас. **Больше нечего желать** — моннан да артыгын көтеп булмый.

**ЖЕЛВА'К** *м. разг.*— төер, оры, каты шеш.

**ЖЕЛЕ'** *нескл. ср.*— 1. желе (желатин белән җимеш суын кушып хәзерләнгән кесәлсыман ашамлык); 2. *(студень)* койка.

**ЖЕЛЕЗА'** *ж. анат.*— биз.

**ЖЕЛЕ'ЗИНА** *ж. простореч.*— тимер кисәге.

**ЖЕЛЕ'ЗИСТЫЙ** I *мин.*— составына тимер кергән, тимерле; *железистые квасцы* — составына тимер кергән (тимерле) ачуташ.

**ЖЕЛЕ'ЗИСТЫЙ** II *анат.*— биз ...-ы; *железистая клетка* — биз күзәнәге.

**ЖЕЛЕЗНОДОРО'ЖНИК** *м.*— тимер юлчы, тимер юлда эшләүче, тимер юлда хезмәт итүче.

**ЖЕЛЕЗНОДОРО'ЖНЫЙ** — 1. тимер юл ...-ы; *железнодорожный мост* — тимер юл

күпере; 2. тимер юлчылар ...-ы; *железнодорожный магазин* — тимер юлчылар магазины.

**ЖЕЛЕ'ЗНЫЙ** — 1. тимер ...-ы; *железная руда* — тимер рудасы; 2. тимер ..., тимердән ясалган; *железная кровать* — тимер кровать; 3. *перен.* нык, тимердәй; *железная дисциплина* — тимердәй (нык) дисциплина. ◇ **За железной решёткой** — таш капчыкта, төрмәдә, тимер читлек эчендә. **Железное дерево** *бот.*— тимер агач. **Железный сон** — каты йокы. **Телега на железном ходу** — тимерле арба.

**ЖЕЛЕЗНЯ'К** *м. мн.* нет — тимер рудасы; *красный железняк* — кызыл тимер рудасы.

**ЖЕЛЕ'ЗО** *ср.*— 1. тимер; 2. *собир.* тимер-томыр әйберләре; *торговать железом* — тимер-томыр әйберләре белән сату итү; 3. *мед.* тимерле дару; *он принимает железо от малокровия* — кан азлыктан ул тимерле дару эчә. ◇ **Кровельное железо** — түбә калае. **Заковать в железо** — *книж. устар.*— богаулау. **Куй железо, пока горячо** *посл.*— тимерне кызуында сук.

**ЖЕЛЕЗОБЕТО'Н** *м. мн.* нет, *тех.*— тимер-бетон (тимер белән бетон катнашмасыннан тора торган төзү материалы).

**ЖЕЛЕЗОБЕТО'ННЫЙ** *тех.* — тимер-бетон ...; *железобетонное сооружение* — тимер-бетон корылма.

**ЖЕЛЕЗОДЕ'ЛАТЕЛЬНЫЙ** *тех.*— тимер эшкәртә торган.

**ЖЕЛЕЗОПЛАВИ'ЛЬНЫЙ** *тех.*— тимер эретә торган, тимер коя торган; *железоплавильный завод* — тимер коя торган завод.

**ЖЕЛЕЗОПРОКА'ТНЫЙ** *тех.* — тимер таптый торган, тимер прокатлау ...-ы (прокатлый торган); *железопрокатный завод* — тимер прокатлау заводы.

**ЖЕЛЕЗОПРОКА'ТЧИК** *м.*— тимер прокатлаучы эшче.

**ЖЕЛЕЗОРЕ'ЗНЫЙ** — тимер кисә торган, тимер кисү ...-ы; *железорезный станок* — тимер кисү станогы; *железорезные ножницы* — тимер кисә торган кайчы.

**ЖЁЛОБ** *м.*— к. жолоб.

**ЖЕЛОБО'К** *м.*— колаша.

**ЖЕЛО'БЧАТЫЙ** *спец.* — колашасыман, улаксыман.

**ЖЁЛТЕНЬКИЙ** *разг.*— сары.

**ЖЕЛТЕ'ТЬ** *несов.*— 1. саргаю, сары төскә керү; 2. *(видне́ться — о жёлтом)* саргаеп тору, сары булып күренү.

**ЖЕЛТЕ'ТЬСЯ** *несов.*— к. желтеть 2.

**ЖЕЛТИЗНА'** *ж. мн.* нет — 1. сарылык; 2. *разг.* сары тап, сары тимгел.

**ЖЕЛТИ'НКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — сары таплар, саргылт төс.

**ЖЕЛТИ'ТЬ** *несов.*— саргайту, сары төскә кертү, сарыга буяу.

**ЖЕЛТКО'ВЫЙ** — йомырка сарысы ...-ы; *желтковая оболочка* — йомырка сарысы пәрдәсе.

**ЖЕЛТО'К** *м.*— йомырка сарысы.

**ЖЕЛТОКО'ЖИЙ** — сары тәнле; *желтокожий человек* — сары тәнле кеше.

**ЖЕЛТОКРА'СНЫЙ** — саргылт кызыл.

**ЖЕЛТОЛИ'ЦЫЙ** — сары чырайлы, сары йөзле, сары тутлы.

**ЖЕЛТОПУ'ЗИК** *м. зоол.*— сары корсак, аяксыз кәлтә (саргылт-соры төстәге елансыман кәлтә).

**ЖЕЛТОРО'ТЫЙ** — 1. *(о птенцах)* сары томшыклы, сары авыз (кош баласы турында); 2. *перен. разг. пренебр.* борын асты кипмәгән, аягына сыер басмаган (тормыш тәҗрибәсе булмаган кеше).

**ЖЕЛТОЦВЕ'Т** *м. бот.*— сары чәчәк (сары чәчәкле үләннәрнең гомуми исеме).

**ЖЕЛТО'ЧНЫЙ** — йомырка сарысы ...-ы; *желточные шарики в протоплазме* — протоплазмада йомырка сарысы шарчыклары.

**ЖЕЛТУ'ХА** *ж. мн.* нет, *мед.*— сары (авыруы), сары төшү.

**ЖЕЛТУ'ШНИК** *м. бот.*— сары баш, тиле торма.

**ЖЕЛТУ'ШНЫЙ** — сары ...; *желтушное заболевание* — сары төшеп авыру.

**ЖЁЛТЫЙ** — сары. ◇ **Жёлтая раса** — сары тәнлеләр. **Жёлтый дом** — акылсызлар йорты.

**ЖЕЛТЬ** *ж. мн.* нет, *хим.*— сары буяу.

**ЖЕЛТЯ'К** *м. бот.*— сары гөмбә.

**ЖЕЛУДЁВЫЙ** — имән чикләвегеннән ясалган, имән чикләвеге ...-ы; *желудёвый кофе* — имән чикләвегеннән ясалган кофе; *желудёвая корка* — имән чикләвеге кабыгы.

**ЖЕЛУ'ДОК** *м.* — 1. *мед.* ашказаны; 2. *(у птиц)* бүтәкә. ◇ **Расстройство желудка** — эч китү. **Желудок варит** — ашказаны эшли. **Жить только одним желудком** — тамакны гына кайгырту, ашау турында гына уйлау.

**ЖЕЛУ'ДОЧЕК** *анат.*— 1. *(часть сердца)* карынчык; 2. *(полость в головном мозге)* куышчык.

**ЖЕЛУ'ДОЧНЫЙ** — 1. ашказаны ...-ы; *желудочный сок* — ашказаны сүле; 2. *разг.* ашказанын дәвалый торган; *желудочные капли* — ашказанын дәвалый торган тамчылар.

**ЖЁЛУДЬ** — к. жолудь.

**ЖЕ'ЛЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ачулы булу, зәһәрлек.

**ЖЕ'ЛЧНЫЙ** — 1. *анат. физиол.* үт ...-ы; *желчный пузырь* — үт куыгы, үт капчыгы; 2. *книж. (раздражительный, злой)* ачулы, тиз ачулanучан, зәһәр.

**ЖЕЛЧЬ** *ж. мн.* нет — 1. *анат. физиол.* үт, үт суы; 2. *разг.* үт капчыгы; 3. *книж. (раздражение)* ярсу, ачу.

**ЖЕМА'НИТЬСЯ** *несов. разг.* — назлану, кылану, кыстату.

**ЖЕМА'ННИЦА** *ж. разг.*— назлы, кыланчык.

**ЖЕМА'ННИЧАТЬ** *несов. разг. пренебр.*— назлы тоту, кыланчыклану.

**ЖЕМА'ННЫЙ** — назлы, кыланчык, кыстатучан.

**ЖЕМА'НСТВО** *ср. мн.* нет — кылану, назлану, назлы кыланыш.

**ЖЕ'МЧУГ** *м.*— энже.

**ЖЕМЧУ'ЖИНА** *ж.* — 1. энже бөртеге; 2. *перен. книж.* хәзинә; *стихи Тукая — жемчужина татарской поэзии* — Тукай шигырьләре — татар поэзиясенең хәзинәсе ул.

**ЖЕМЧУ'ЖНЫЙ** — 1. энже ...; *жемчужное ожерелье* — энже муенса; 2. *перен. поэт.* энҗе кебек, энҗесыман, энҗедәй; *жемчужные зубы* — энҗе кебек тешләр. ◇ **Жемчужные строки** — вак, матур язу.

**ЖЕНА'** *ж.*— хатын (ир хатыны).

**ЖЕНА'ТЫЙ** — өйләнгән, хатынлы.

**ЖЕ'НИН** *разг.*— хатынның, хатынныкы; *женин портрет* — хатыны(м)ның портреты.

**ЖЕНИ'ТЬ** *сов.* и *несов.*— өйләндерү, хатын алып бирү. ◇ **Без меня меня женили** — минем үзем юкта өйләндергәннәр (кешегә үзенең ризалыгыннан башка берәр эш йөкләү турында әйтелә).

**ЖЕНИ'ТЬБА** *ж. мн.* нет — өйләнү.

**ЖЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.*— өйләнү.

**ЖЕНИ'Х** *м.* — 1. кияү, кияү буласы кеше, кыз ярәшкән егет; 2. *разг. фам. (молодой человек)* житкән егет, кияү булырлык егет, өйләнерлек егет. ◇ **Смотреть женихом** *разг.*— шат күренү, шат күңелле булу.

**ЖЕНИХО'ВСКИЙ** *разг.*— кияү ...-ы; *жениховский подарок* — кияү бүләге.

**ЖЕНОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж.* — хатын-кызларны бик яратучан.

**ЖЕНОНЕНАВИ'СТНИК** *м. книж.*— хатын-кызларны яратмаучы, хатын-кызлардан качучы, хатын-кызларны дошман күрүче.

**ЖЕНОНЕНАВИ'СТНИЧЕСКИЙ** — хатын-кызларны яратмый торган, хатын-кызлардан кача торган, хатын-кызларны дошман күрә торган.

**ЖЕНОПОДО'БНЫЙ** — хатыз-кызга охшаган, хатын-кыз төсле.

**ЖЕ'НСКИЙ** — хатын-кыз ...-ы; хатын-кызлар ...-ы; *женский почерк* — хатын-кыз кулы (язуы); *женский праздник* — хатын-кызлар бәйрәме. ◇ **Женский род** *грам.*— женский род.

**ЖЕ'НСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — нәфислек, гүзәллек, мөлаемлык, йомшаклык.

**ЖЕ'НСТВЕННЫЙ** *книж.*— нәфис, гүзәл, мөлаем, йомшак, хатын-кызларга хас.

**ЖЕ'НЩИНА** *ж.*— 1. хатын кеше; 2. хатын-кыз.

**ЖЕРДЕВО'Й** *обл.*— киртәлек ..., колгалык ...; *жердевой лес* — киртәлек урман, киртәлек агачлар.

**ЖЁРДОЧКА** *ж.* — 1. *(шест)* кечкенә киртә, кечкенә колга; 2. *(перекладина в птичьей клетке)* кунача.

**ЖЕРДЬ** *ж.*— 1. киртә, колга; 2. *разг. фам. шутл.* колгасар, озын кеше.

**ЖЕРЁБАЯ** — буаз (бия, ишәк).

**ЖЕ'РЕБЕЙ** *м. обл.*— к. жребий.

**ЖЕРЕБЁНОК** *м. (мн.* жеребята) — 1. *(до одного года)* колын; 2. *(на втором году)* кырыкмыш, кырыкмыш тай; 3. *(на третьем году)* тай.

**ЖЕРЕБЕ'Ц** *м.*— айгыр.

**ЖЕРЕБИ'ТЬСЯ** *несов.* — колынлау (бия, ишәк турында).

**ЖЕРЁБОСТЬ** *ж. обл. спец.* — буазлык (бия, ишәк турында).

**ЖЕРЕ'БЧИК** *м.*— яшь айгыр.

**ЖЕРЕБЬЁВКА** *ж.*— жирәбә салу, шобага салу, таяк тотышу.

**ЖЕРЕБЯ'ТИНА** *ж. мн.* нет — колын ите, тай ите.

**ЖЕРЕБЯ'ЧИЙ** — 1. колын ...-ы; тай ...-ы; *жеребячья гривка* — колын ялы, тай ялы; 2. *перен. разг. фам.* артык шаян, колын кебек уйнаклап тора торган; *жеребячье настроение* — шаян настроение.

**ЖЕРЕБЯ'ЧИТЬСЯ** *несов., разг. фам.* — артык шаяру, баскан урында тик тора алмау.

**ЖЕ'РЕХ** *м. обл.*— опты (балык).

**ЖЕ'РЛИ'ЦА** *ж. обл.*— чуртан кармагы.

**ЖЕРЛО'** *ср. книж.*— авыз, тишек; *жерло пушки* — пушка авызы.

**ЖЁРНОВ** *м.*— к. жорнов.

**ЖЕ'РТВА** *ж. книж.* — 1. корбан; 2. *перен.* авырлык, кыенлык, үзен корбан итү; *советские люди готовы на любые жертвы ради любимой Родины* — совет кешеләре сөекле Ватан өчен теләсә нинди авырлыкларга (үзләрен корбан итүгә) хәзер торалар; 3. *устар. (пожертвование)* иганә, бүләк. ◇ **Принести жертву** — корбан итү.

**ЖЕ'РТВОВАТЕЛЬ** *м. устар.*— иганә бирүче.

**ЖЕ'РТВОВАТЬ** *несов.*— 1. *(приносить в дар)* бүләк итеп бирү; иганә итү; 2. *перен.* корбан итү, фида итү, үзен аямау; *жертвовать собой* — үзен корбан итү.

**ЖЕРУ'ХА** *ж. бот.* — бөергән, су борычы.

**ЖЕСТ** *м.* — 1. ым, ишарә, тән хәрәкәте, кул хәрәкәте, селтәнү (тойгы һәм фикерләрне белдерү өчен); 2. *перен.* күрсәтмә кыланыш.

**ЖЕСТИКУЛИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— (сөйләгәндә) кулларны селтәү.

**ЖЕСТИКУЛЯ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — кулларны селтәү (сөйләгәндә).

**ЖЁСТКИЙ** — 1. каты; *жёсткий диван* — каты диван; *жёсткие волосы* — каты чәч; *жёсткая вода* — каты су; 2. *перен.* тупас, каты; *жёсткий характер* — тупас (каты) характер; 3. *перен.* кискен; катгый; *жёсткие сроки* — катгый сроклар; *жёсткие условия* — кискен шартлар.

**ЖЁСТКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. катылык; 2. *перен. (суровость)* рәхимсезлек, мәрхәмәтсезлек, кансызлык, тупаслык; 3. *перен. (безоговорочность)* кискенлек, катгыйлык.

**ЖЕСТО'КИЙ** — 1. *(беспощадный, безжалостный)* каты күңелле, аяусыз, рәхимсез, кансыз, мәрхәмәтсез; 2. бик көчле, бик нык,

бик каты; *жестокая борьба* — бик каты көрәш; *жестокое сопротивление* — каты каршылык. ◇ Жестокая необходимость *книж.* — котылгысыз кирәклек, үтә зарурлык. Жестокие морозы — чатнап торган (чатнама) салкыннар.

**ЖЕСТО'КО** *нареч.* — 1. бик каты, бик нык; *вы жестоко ошибаетесь* — сез бик нык (каты) ялгышасыз; 2. аяусыз рәвештә, рәхимсез рәвештә.

**ЖЕСТОКОСЕ'РДИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — каты күңеллелек, мәрхәмәтсезлек, кансызлык, аяусызлык, шәфкатьсезлек, миһербансызлык.

**ЖЕСТОКОСЕ'РДНЫЙ** *книж.* — каты күңелле, мәрхәмәтсез, кансыз, аяусыз, шәфкатьсез, миһербансыз.

**ЖЕСТО'КОСТЬ** *ж.* — 1. (*безжалостность*) катылык, рәхимсезлек, кансызлык, мәрхәмәтсезлек; 2. (*жестокий поступок*) каты мөгамәлә, каты чара.

**ЖЕСТЬ** *ж. мн.* нет — калай; *кровельная жесть* — түбә калае.

**ЖЕСТЯ'НКА** *ж.* — 1. (*коробка из жести*) калай савыт, калай банка, калай тартма; 2. *разг.* (*кусочек жести*) калай кисәге.

**ЖЕСТЯНО'Й** — калай ...; *жестяной чайник* — калай чәйнек.

**ЖЕСТЯ'НЩИК** *м.* — чиләк төпләүче, калайчы, суык тимерче (калайдан әйберләр ясаучы).

**ЖЕСТЯ'НЫЙ** — к. жестяной.

**ЖЕТО'Н** *м.* — жетон (1. медаль яки металл значок; 2. берәр әйбер, мәсәлән, кассадан акча алу өчен бирелә торган калай кисәге).

**ЖЕЧЬ** *несов.* — 1. яндыру; *жечь бумагу* — кәгазьне яндыру; 2. ягу; *жечь много дров* — күп утын ягу; 3. яндыру, кыздыру, көйдерү; көйдереп алу, пешерү; *солнце жжёт* — кояш кыздыра; 4. чеметтерү, чеметтереп алу; *мороз жжёт лицо* — суык битне чеметтереп ала; 5. чагу; *крапива жжёт* — кычыткан чага; 6. (*о кислоте*) яндыру, ачыттыру; 7. *перен. книж.* — яндыру, кайгыга төшерү, борчу тудыру.

**ЖЕ'ЧЬСЯ** *несов.* — 1. пешү; 2. *разг.* чагу; *крапива жжётся* — кычыткан чага; 3. *разг.* пешерү; *утюг жжётся* — үтүк пешерә; 4. *страд.* ягылу; *дрова жгутся неэкономно* — утын бәрәкәтсез ягыла.

**ЖИВА'ЛЫЙ** *обл.* — дөнья күргән, тәҗрибәле, күпне күргән.

**ЖИВА'ТЬ** *многокр. разг.* — торгалау.

**ЖИВЕ'НЬКО** *нареч.*, *простореч. фам.* — бик тиз, күз ачып йомганчы, җәһәт.

**ЖИВЕ'Ц** *м.* — җимбалык, маймыч, тере маймыч (зур балыкны эләктерү өчен кармакка кидерелгән кечкенә тере балык).

**ЖИВИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — көч бирә торган, хәл кертә торган, терелтә торган; яшәртеп җибәрә торган; дәртләндереп җибәрә торган.

**ЖИВИ'ТЬ** *несов.*, *книж. поэт.* — терелтү; көч кертү; дәртләндерү, җанландыру, рухландыру.

**ЖИВИ'ТЬСЯ** *несов. устар.* — табышлану, файдалану.

**ЖИВИ'ЦА** *ж.* — сагыз, сыткы сагыз (ылыслы агачлардан ага торган сумала).

**ЖИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. йорт кошлары; 2. *обл.* исән вакыт; *при живности отца* — әти исән вакытта.

**ЖИ'ВО** *нареч.* — 1. бик ачык итеп, бик анык итеп, ап-ачык итеп; *он живо представил старика* — ул картны бик ачык итеп күз алдына китерде; 2. рухлы, күтәренке рух белән, җанлы; *пьесу играли очень живо* — пьесаны бик күтәренке рух белән уйнадылар; 3. *разг.* бик тиз, тиз генә, елдам гына, җәһәт кенә; *он живо сбегал за доктором* — ул тиз генә докторны алып килде.

**ЖИВОГЛО'Т** *м.* *просторечь.* — тереләй тунаучы, кан эчүче, мир ашаучы, байгура.

**ЖИВОДЁР** *м. бран.* — 1. тире тунаучы (әлектә үлгән терлекләрнең тиресен тунау белән шөгыльләнүче); 2. *перен.* тереләй тунаучы, кычкыртып талаучы (эксплуататор); 3. *перен. просторечь.* рәхимсез, шәфкатьсез.

**ЖИВОДЁРСТВО** *ср. мн.* нет, *просторечь.* — 1. кансызлык (терлекләргә карата); 2. *перен.* тереләй тунау, кычкыртып талау (сәүдәгәрләр, спекулянтлар, кулаклар турында).

**ЖИВО'Й** — 1. тере, исән, исән-сау; *его родители ещё живы* — аның ата-аналары әле исән-сау; 2. тере; *живая рыба* — тере балык; 3. җанлы, чын, табигый; *живой пример героизма* — героизмның җанлы мисалы; *живые факты* — чын фактлар; *изобразить живых людей* — чын кешеләрне сурәтләү; *живые цветы* — табигый чәчәкләр, чын чәчәкләр; 4. җанлы; *живая беседа* — җанлы беседа; 5. тере, елгыр, житез, хәрәкәтчел; *живой ребёнок* — тере бала; *живые глаза* — хәрәкәтчел күзләр; 6. җанлы, җиңел; *живое описание* — җанлы тасвирлау; 7. тормыш өчен әһәмиятле, тормыш өчен кирәкле; *живое дело* — тормыш өчен кирәкле эш; 8. тирән тәэсирле; кискен кичерешле; *живое воспоминание* — тирән тәэсирле истәлек; *живая обида* — тирән тәэсирле үпкә. ◇ **Живой вес** — тереләй авырлык; тере килеш авырлык. **Живая рана** — төзәлмәгән яра. **Живое предание** — 1. буыннан буынга сөйләнеп килгән риваять; 2. хәзергә кадәр яши торган, яшәп килгән. **Живая изгородь** — үсемлек киртә, койма. **Живая природа** — тере табигать (хайваннар һәм үсемлекләр). **Живая вода** — тереклек суы (әкиятләрдә). **Живой портрет** — нәкъ ... төсле; *сын живой портрет своего отца* — улы нәкъ әтисе төсле. **Живого места нет** — зарарланмаган урыны калмаган. **На живую нитку, на живую руку** *разг.* — ашыгып аннан-моннан гына эшләү, әшер-мошер генә эшләп ташлау. **Ни одной живой души** — бер генә җан иясе дә юк. **Задеть за живое** — авырткан урынына кагылу, яратмаган нәрсәсе турында әйтү. **Живой язык** — 1. җанлы тел,

хәзерге тел; 2. сөйләү теле. **Ни жив, ни мёртв** *разг.* — коты алынган, коты чыккан (куркудан).

**ЖИ'ВОКОСТЬ** *ж. бот.* — испәрәк (чүп үлән).

**ЖИВОПИСА'ТЬ** *сов.* и *несов.*, *книж. устар.* — җанлы итеп сурәтләү, җанлы итеп язу.

**ЖИВОПИ'СЕЦ** *м. устар.* — художник.

**ЖИВОПИ'СНО** *нареч.* — матур, рәсемдәге кебек.

**ЖИВОПИ'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — матурлык, рәсемдәге кебек булу.

**ЖИВОПИ'СНЫЙ** — 1. рәсем ясау ...-ы; *живописное искусство* — рәсем ясау сәнгате; 2. матур, рәсемдәге шикелле; *живописный вид* — матур күренеш; *живописная местность* — матур урын.

**ЖИ'ВОПИСЬ** *ж. мн.* нет — 1. сынлы сәнгать; *уроки живописи* — сынлы сәнгать дәресләре; 2. *собир.* картиналар (буяулар белән ясалган рәсемнәр).

**ЖИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — җанлылык, терелек; житезлек, үткенлек. ◇ **С живостью** — 1. җанлы рәвештә, җанлы итеп; 2. бик тиз.

**ЖИВО'Т** *м.* — 1. корсак, эч, карын; 2. *устар, разг.* җан, тормыш; *не жалеть живота* — җанны кызганмау (сугышу). ◇ **Надорвать живот** *разг.* — көлә-көлә эч кату; арыганчы көлү. **Живот подвело** *разг.* — карын ачты. **Живот схватило** — эч бора башлады. **Положить живот** — үзеңне корбан итү. **Не на живот, а на смерть** — үз-үзеңне аямыйча.

**ЖИВОТВОРИ'ТЬ** *несов., книж. устар.* — терелтү, җанландыру, рухландыру, хәл кертү, көч бирү.

**ЖИВОТВО'РНО** *нареч.*: **подействовать животворно** — җанландырып җибәрү, рухландырып җибәрү, дәртләндереп җибәрү.

**ЖИВОТВО'РНЫЙ** — җанландыра торган, җанландыргыч, рухландыра торган; дәртләндерә торган; яшәү көче бирә торган; *животворный советский патриотизм* — яшәү көче бирә торган совет патриотизмы.

**ЖИВОТИ'НА** *ж. простореч. обл.* — 1. йорт хайваны; 2. *только ед. собир.* терлек, мал-туар, йорт хайваннары; 3. (*о животе*) зур корсак, кап корсак.

**ЖИВОТНОВО'Д** *м. книж.* — терлекче, терлек караучы, терлек асраучы (терлекчелек белгече).

**ЖИВОТНОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — терлек асрау, терлек асраучылык, терлекчелек.

**ЖИВОТНОВО'ДЧЕСКИЙ** — терлекчелек ...-ы; *животноводческий совхоз* — терлекчелек совхозы.

**ЖИВО'ТНОЕ** *ср.* — 1. тереклек иясе; 2. хайван; 3. *бран.* хайван (юньсез, тупас кеше турында).

**ЖИВО'ТНЫЙ** — 1. хайваннар ...-ы; *животный мир* — хайваннар дөньясы; 2. хайваннарча ..., хайвани; *животный страх* — хайваннарча курку; *животная страсть* — хайвани дәрт. ◇ **Животный эпос** — хайваннар турындагы хикәя. **Животный орнамент** — хайваннар сурәтеннән гыйбарәт орнамент.

**ЖИВОТРЕПЕ'ЩУЩИЙ** — 1. тырпылдап тора торган, тере; *животрепещущие ерши* — тырпылдап тора торган шыртлакалар; 2. *перен.* актуаль, көн үзәгендәге, бүгенге көн өчен иң әһәмиятле, иң мөһим; *животрепещущий вопрос* — актуаль мәсьәлә; 3. *разг. шутл.* дерелдәп, селкенеп тора торган; *животрепещущий мостик* — селкенеп тора торган күпер.

**ЖИВУ'ЧЕСТЬ** *ж. мн.* нет — яшәүчәнлек, яшәүгә сәләтлелек.

**ЖИВУ'ЧИЙ** — 1. (*жизнеспособный*) яшәүчән, яшәргә сәләтле; 2. *перен.* (*устойчивый*) тиз бетми торган, гомерлек.

**ЖИВУ'ЧКА** *ж. бот.* — яра үләне, кәрләч.

**ЖИ'ВЧИК** *м.* — 1. *разг.* (*живой, подвижный человек*) тере, җитез, өлгер, елгыр; 2. *биол.* аталык орлыгы, сперматозоид. ◇ **Живчик прыгает** — кан тамыры тибә.

**ЖИВЬЁМ** *нареч. простореч.* — терелэй, тере килеш, терелэтә.

**ЖИГА'ЛКА** *ж. зоол.* — көзге чебен, чаккыч чебен.

**ЖИГАНУ'ТЬ** *сов. простореч.* — чыжылдату, сызу (камчы яки чыбык белән сугу).

**ЖИДЕ'ЛЬ** *ж. мн.* нет, *простореч.* — 1. су (бик сыек ашамлык турында); *налили какую-то жидель* — ниндидер су салдылар шунда; 2. бик сирәк (тукыманың сыйфаты турында); *это сукно совсем жидель* — бу сукно бик сирәк (тукылган сукно).

**ЖИ'ДЕНЬКИЙ** — сыек кына, бик сыек.

**ЖИ'ДКИЙ** — 1. сыек; *жидкое молоко* — сыек сөт; 2. сирәк; *жидкий лес* — сирәк урман; 3. *перен.* зәгыйфь, көчсез; *жидкий голос* — көчсез тавыш. ◇ **Жидкие аргументы** *разг. пренебр.* — төпсез аргументлар, төпсез дәлилләр. **Жидкая речь** *разг. пренебр.* — сай эчтәлекле речь. **Жидкие познания** *разг. пренебр.* — сай белемнәр. **Жидкий мостик** *простореч.* — селкенеп тора торган күпер. **Жидкая жердь** *простореч.* — нечкә, бөгелә торган колга. **Жидкие волосы** — сирәк чәч.

**ЖИДКОКО'СТНЫЙ** *ирон.* — чандыр.

**ЖИДКОНО'ГИЙ** *простореч.* — саламсыйрак.

**ЖИ'ДКОСТЬ** *ж.* — 1. сыекча; *меры жидкостей* — сыекчалар үлчәве; 2. сыеклык; *жидкость клея* — җилемнең сыеклыгы; 3. сирәклек; *жидкость волос* — чәчнең сирәклеге.

**ЖИЗНЕДЕ'ЯТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. *биол.* тереклек эшчәнлеге; *жизнедеятельность организма* — организмның тереклек эшчәнлеге; 2. *устар.* эшчәнлек.

**ЖИЗНЕДЕ'ЯТЕЛЬНЫЙ** — 1. тереклек эшчәнлегенә сәләтле; *жизнедеятельный организм* — тереклек эшчәнлегенә сәләтле организм; 2. җитез, булдыклы, эшлекле; *жизнедеятельный человек* — булдыклы кеше, эшлекле кеше.

**ЖИ'ЗНЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — яшәүчәнлек, актуальлек, кирәклелек, әһәмиятлелек; *сила и жизненность советского строя* — совет строеның көче һәм яшәүчәнлеге.

**ЖИ'ЗНЕННЫЙ** — 1. тормыш ... -ы; *жизненный опыт* — тормыш тәҗрибәсе; 2. тормыш өчен кирәкле; *жизненные припасы* — тормыш өчен кирәкле әйберләр; 3. әһәмиятле, мөһим, кирәкле, актуаль; *жизненные вопросы* — әһәмиятле мәсьәләләр.

**ЖИЗНЕОПИСА'НИЕ** *ср. книж. устар.* — тәрҗемәи хәл, биография.

**ЖИЗНЕОЩУЩЕ'НИЕ** *ср. книж.* — чынбарлыкны тою (сизү).

**ЖИЗНЕПОНИМА'НИЕ** *ср. книж.* — тормышны аңлау, тормышка караш.

**ЖИЗНЕРА'ДОСТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — шат күңеллелек, көр күңеллелек.

**ЖИЗНЕРА'ДОСТНЫЙ** — шат күңелле, көр күңелле.

**ЖИЗНЕСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — яшәүгә сәләтлелек.

**ЖИЗНЕСТО'ЙКИЙ** *книж.* — нык.

**ЖИЗНЕСТО'ЙКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ныклык.

**ЖИЗНЬ** *ж.* — 1. *только ед.* тормыш; *жизнь человека* — кешенең тормышы; *провести решение в жизнь* — карарны тормышка ашыру; 2. гомер; *в течение всей его жизни* — бөтен гомере буена; 3. *только ед.* җанлылык, хәрәкәт; *улицы полны жизни* — урамда зур җанлылык; *на улице никакой жизни нет* — урамда бернинди хәрәкәт юк. 4. *устар.* җан, кеше; *фашисты загубили немало жизней* — фашистлар бик күп җан кыйдылар. 5. тереклек; *утробная жизнь* — ана карынындагы тереклек; 6. *филос.* (*бытие*) яшәеш, чынбарлык. ◇ **По жизнь** *устар.* — гомергә, үлгәнчегә кадәр. **Ни в жизнь** *разг. фам.* — беркайчан да, һичбер вакытта да. **Вопрос жизни и смерти** *книж.* — бик әһәмиятле мәсьәлә, чиктән тыш мөһим мәсьәлә. **Бороться не на жизнь, а на смерть** — үз-үзеңне аямыйча көрәшү. **Лишить жизни** — үтерү. **Даровать жизнь** — гафу итү, кичерү, үлем җәзасыннан коткару. **Находиться между жизнью и смертью** — яшәү белән үлем арасында тору, кыл өстендә тору. **По гроб жизни** — үлгәнче. **На всю жизнь** — гомергә. **Жизнь моя** *разг.* — кадерлем, җаным. **Спасти кому-н. жизнь** — үлемнән коткару. **Жизнь бьёт ключом** — тормыш кайнап тора. **Посягать на жизнь** — үтермәкче булу. **Покончить с жизнью** — үзен-үзе үтерү. **Тусклая жизнь** — кызыксыз тормыш.

**ЖИ'ЛА** I *ж.* — 1. тамыр, кан тамыры, кан юлы; 2. (*сухожилие*) сеңер; 3. *горн.* катлам; *золотоносная жила* — алтынлы катлам. ◇ **Тянуть жилы** *разг.* — җелеген суыру.

**ЖИ'ЛА** II *м.* и *ж.*, *простореч. неодобр.* — саран, карун.

**ЖИЛЕ'Т** *м.* — жилет (өс киеме).

**ЖИЛЕ'ТКА** *ж.* — жилет.

**ЖИЛЕ'Ц** *м.* — торучы, фатирчы, квартирант; *жилец нашего дома* — безнең йортта торучы. ◇ **Не жилец на свете** — гүр якасында тора, озак яшәмәс.

**ЖИ'ЛИСТЫЙ** — 1. сеңерле; *жилистое мясо* — сеңерле ит; 2. тамырлы, калын тамырлы; *жилистая рука* — калын тамырлы кул; 3. *перен. разг.* нык, көчле; *жилистый мужчина* — нык ир.

**ЖИ'ЛИТЬСЯ** I *несов. простореч.* — көчәнү, азаплану.

**ЖИ'ЛИТЬСЯ** II *несов. простореч. неодобр.* — саранлашу, кысу.

**ЖИЛИ'ЦА** *ж.* — к. жилец.

**ЖИЛИ'ЩЕ** *ср. книж.* — торак, йорт.

**ЖИЛИ'ЩНЫЙ** *книж.* — торак ... -ы; тораклар...-ы; *жилищное строительство* — тораклар төзелеше.

**ЖИ'ЛКА** I *ж.* — 1. к. жила I; 2. *бот. зоол.* җепсел (үсемлек яфракларындагы һәм бөҗәк канатларындагы җепселләр); 3. тамыр; *белый мрамор с красными жилками* — кызыл тамырлы ак мрамор.

**ЖИ'ЛКА** II *ж. мн.* нет — сәләт; *у него есть организаторская жилка* — аның оештыру сәләте бар.

**ЖИЛО'Й** — 1. торак ... ; *жилой дом* — торак йорт; 2. кешеләр тора торган, торырга яраклы; *жилая комната* — кешеләр тора торган (торырга яраклы) бүлмә.

**ЖИЛПЛО'ЩАДЬ** *ж.* — торак мәйданы.

**ЖИЛСТРОИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — тораклар төзелеше, тораклар төзү.

**ЖИЛЬЁ** *ср. разг.* — 1. кеше яши торган җир, яши торган җир; *вдали от человеческого жилья* — кеше яши торган җирдән еракта; 2. *простореч.* (*жилище*) торак; 3. *разг.* тору; *годный для жилья* — тору өчен яраклы.

**ЖИМ** *м. спорт.* — кысу көче, кысу.

**ЖИ'МОЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *бот.* — зелпе (куак агач).

**ЖИР** *м.* — май. ◇ **Нагулять жиру** *разг.* — май җыю, симерү. **Заплыть жиром** — май белән каплану, артык симерү. **С жиру беситься** *разг.* — маена чыдый алмау.

**ЖИРА'Ф** *м.*, **ЖИРА'ФА** *ж. зоол.* — жираф (Африкада яшәүче хайван).

**ЖИРЕ'ТЬ** *несов. разг.* — симерү.

**ЖИ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. симезлек; 2. (*насыщенность жиром*) майлылык.

**ЖИ'РНЫЙ** — 1. симез, майлы; *жирное мясо* — симез ит; 2. өреле, чырлы, майлы; *жирный суп* — өреле аш; 3. *разг.* симез, тук; *жирный кот* — симез мәче. 4. куе; *жирное молоко* — куе сөт; 5. (*о почве*) ашлы; (*о глине*) үзле, сутлы; 6. майлы, майланган, майга буялган, майланып беткән; *жирные руки* — майлы куллар. ◇ **Жирный шрифт** — кара шрифт, калын хәреф. **Жирный кусок** *перен. разг.* — симез калҗа (кызыктырырлык нәрсә).

**ЖИРОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *тех.* майландыру, май белән туендыру; 2. (*о живот-*

*ных)* май жыю, симерү; *кабаны жируют в болотах* — кабан дуңгызлары сазлыкта йөреп симерәләр; 3. *спец.* (*о деревьях*) җимеш бирмичә буйга үсү.

**ЖИРОВИ'К** *м. обл., мед.* — май шеше.

**ЖИРОВО'Й** — май ...-ы; *жировая железа* — май бизе; *жировая промышленность* — май промышленносте. ◇ **Жировое яйцо** — тәңкәсез йомырка; кабыксыз салынган йомырка.

**ЖИРО'К** *м. разг.* — май, май кисәге.

**ЖИРОМОЛО'ЧНЫЙ** *с.-х.* — куе сөтле; *жиромолочный скот* — куе сөтле терлек.

**ЖИРООТЛОЖЕ'НИЕ** *ср.* — май җыелу, май утыру (тәнгә).

**ЖИРОТО'П** *м. спец.* — май кайнатучы, май эретүче.

**ЖИРОТО'ПНЫЙ** — май кайнату ...-ы; май кайната торган; май эретү ...-ы; май эретә торган; *жиротопный цех* — май кайнату цехы.

**ЖИТЕ'ЙСКИЙ** *разг.* — көндәлек, көн дә була торган, гадәттәге; *разговор на житейскую тему* — гадәттәге (көндәлек) темага сөйләшү. ◇ **Дело житейское** *разг.* — тормышта була торган эш; гадәттә була торган эш.

**ЖИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ЖИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — торучы, яшәүче; торучы халык, ... халкы; *жители города* — шәһәрдә торучы халык; шәһәр халкы.

**ЖИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет—тору, яшәү; *место жительства* — тору урыны. ◇ **Вид на жительство** *устар.* — паспорт.

**ЖИ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов. офиц. устар.* — тору, яшәү.

**ЖИТИЕ'** *ср.* — 1. *церк.* — тормыш; *жития святых* — изгеләрнең тормышлары; 2. *книж. устар.* биография, тәрҗемәи хәл.

**ЖИ'ТНИЦА** *ж. книж.* — 1. *устар.* амбар, келәт; 2. *перен.* игенгә бай җир, ашлыкка бай җир (өлкә).

**ЖИТНЯ'К** *м. бот.* — арышбаш (кыяклы азык үлән).

**ЖИ'ТНЫЙ** — 1. арыш ...-ы; *житный хлеб* — арыш икмәге; 2. арпа ...ы; *житная крупа* — арпа ярмасы. ◇ **Житный двор** *устар.* — запас иген (ашлык) тутырылган складлар.

**ЖИ'ТО** *ср. мн.* нет — иген, ашлык (Украинада — арышны, төньякта — арпаны, көнчыгышта сабан ашлыкларын „жито" дип атыйлар).

**ЖИТЬ** *несов.* — яшәү, тору. ◇ **Здоро́во живёшь** *разг.* — һичбер сәбәпсез, тик торганда. **Приказал долго жить** — үлде.

**ЖИТЬЁ** *ср. мн.* нет, *разг.* — 1 тормыш, көнкүреш; *житьё его не плохое* — аның тормышы начар түгел; 2. тору, яшәү; *житьё на чужой счёт* — кеше җилкәсендә яшәү; 3. тору; *дом, пригодный для житья* — торыр өчен яраклы өй. ◇ **Житья нет** — көн юк. **Житьё-бытьё** — тормыш, көнкүреш.

**ЖИ'ТЬСЯ** *безл. несов., разг.* — яшәү, тору; *ему хорошо живётся* — ул яхшы тора.

**ЖМОТ** *м. простореч. обл.* — саран, карун.

**ЖМУ'РИТЬ** *несов.:* **жмурить глаза** — күз кысу.

**ЖМУ'РИТЬСЯ** *несов.* — күзләрне кысу.

**ЖМУ'РКИ** *ед.* нет — сукыр тәкә уены, күзбәйләш уены.

**ЖМЫ'ХИ** *мн. с.-х.* — түп (майлы орлыкларның маен чыгарганнан соң калган сыгынты).

**ЖМЫ'ХОВЫЙ** *с.-х.* — түп...; *жмыховый корм* — түп азык.

**ЖМЫХОДРОБИ'ЛКА** *ж. с.-х.* — түп ваклагыч.

**ЖНЕ'ЙКА** *ж. с.-х.* — уру машинасы, ургыч.

**ЖНЕЦ** *м. с.-х.* — уракчы.

**ЖНЕЯ'** *ж. обл.* — 1. к. жница; 2. к. жнейка.

**ЖНИ'ВО** *ср. обл.* — к. жнивьё.

**ЖНИВЬЁ** *ср.* — 1. урылган җир; 2. *только ед.* (*стерня*) камыл; 3. *только ед. обл.* урак өсте.

**ЖНИТВО'** *ср. мн.* нет — к. жнивьё 2,3.

**ЖНИ'ЦА** *ж.* — уракчы (хатын-кыз).

**ЖОКЕ'Й** *м. спорт.* — жокей (ат өйрәтүче).

**ЖО'ЛОБ, ЖЁЛОБ** *м.* — улак, колаша, ялгаш.

**ЖО'ЛУДЬ, ЖЁЛУДЬ** *м.* — имән чикләвеге.

**ЖОМ** *м.* — 1. пресс, эскәнҗә; 2. (*выжимки*) түп; сыгынты; 3. *простореч. обл.* карун.

**ЖОНГЛЁР** *м.* — жонглёр (циркта).

**ЖОНГЛЁРСТВО** *ср. мн.* нет — 1. жонглёрлык; 2. *перен. книж.* уйнау; *жонглёрство словами* — сүз белән уйнау.

**ЖОНГЛИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. жонглёрлык итү; 2. *перен. книж.* уйнау; *жонглировать цитатами* — цитаталар белән уйнау.

**ЖО'РНОВ, ЖЁРНОВ** *м.* (*мн.* жернова́) — тегермән ташы.

**ЖОХ** *м. простореч. обл.* — хәйләкәр, мут, алдакчы.

**ЖРАТВА'** *ж. мн.* нет, *простореч. вульг.* — 1. к. жрать; 2. (*пища*) ашамлык.

**ЖРАТЬ** *несов. простореч. вульг.* — бүсү, тыгыну, ашау.

**ЖРЕ'БИЙ** *м.* — 1. шобага, җирәбә; *бросать жребий* — җирәбә салу; 2. *перен. книж. устар.* язмыш, тәкъдир; *такой уж мой жребий* — минем язмышым шундый инде. ◇ **Жребий брошен** — тәвәккәлләдек, ни булса ул булыр.

**ЖРЕЦ** *м. книж.* — 1. *рел.* жрец (мәҗүсиләрдә дин башлыгы); 2. *перен., ритор. поэт.* ата, белгеч; *жрецы науки и искусства* — фән һәм сәнгать аталары (белгечләре).

**ЖРИ'ЦА** *ж.* — к. жрец 1.

**ЖУ'ЖЕЛИЦА** *ж. зоол.* — бызылдавык, бызлавык, сасы коңгыз (коңгызлар семьялыгыннан бөҗәк).

**ЖУЖЖА'ТЬ** *несов.* — 1. (*о насекомых*) бызлау, бызылдау, безелдәү; 2. гөжләү, гөж

килү; *толпа жужжат* — халык төркеме гөж килә. 3. выжлау, выжлап очу, сызгыру; *пули жужжат над головой* — пулялар баш очыннан выжлап очалар.

**ЖУК** *м.* — 1. *(насекомое)* коңгыз; 2. *перен.* алдакчы, хәйләкәр.

**ЖУ'ЛИК** *м.* — 1. *(вор)* жулик, карак, кесә карагы, сукбай; 2. *(обманщик)* алдакчы, алдаучы, жулик.

**ЖУЛИКОВА'ТЫЙ** *разг.* — жулиграк, жуликка тартым; хәйләкәр; жуликсыман; *жуликоватый вид* — жуликсыман кыяфәт.

**ЖУЛЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир. разг.* — 1. жуликлар, караклар, сукбайлар; 2. *(обманщики)* алдакчылар, хәйләкәрләр.

**ЖУ'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. разг.* — алдашу, алдау, хыянәт итү.

**ЖУ'ЛЬНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *простореч.* — к. жульничать.

**ЖУПА'Н** *м. истор.* — жупан, кыска чикмән (элек полякларда һәм украиналыларда).

**ЖУ'ПЕЛ** *м. книж.* — бүки, куркыткыч, карачкы.

**ЖУРАВЕ'ЛЬНИК** *м. бот.* — саз яраны (яранчалар семьялыгыннан чүп үләне).

**ЖУРАВЛЁНОК** *м.* (*мн.* журавлята) — торна бәпкәсе, бала торна.

**ЖУРАВЛИ'НЫЙ** — 1. торна ...-ы; *журавлиное перо* — торна йоны, торна каурые; 2. торнача, торна кебек; *журавлиная походка* — торнача (торна кебек) йөрү.

**ЖУРАВЛИ'ХА** *ж. разг.* — ана торна.

**ЖУРА'ВЛЬ** *м.* — 1. *(птица)* торна; 2. *обл.* *(у колодца)* кое сиртмәсе. ◇ **Журавль в небесах, а синица в руках**—һавадагы торнаны тотам дип, кулыңдагы чыпчыкны ычкындырма (күпне көтеп аздан коры калма дигән мәгънәдә).

**ЖУРИ'ТЬ** *несов. разг.* — шелтәләү, әрләү.

**ЖУРИ'ТЬСЯ** *несов. обл.* — кайгыру, пошыну, борчылу, көенү.

**ЖУРНА'Л** *м.* — журнал.

**ЖУРНАЛИ'СТ** *м.* — журналист (1. газета-журналларда эшләүче; 2. канцеляриядә керем-чыгым журналларын алып баручы хезмәткәр).

**ЖУРНАЛИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — журналистика (1. газета-журналлар; 2. газета-журналларда әдәби публицистик эшчәнлек).

**ЖУРНАЛИ'СТКА** *ж.* — к. журналист.

**ЖУРНАЛИ'СТСКИЙ** — журналист ...-ы; журналистлык ...-ы; *журналистская способность* — журналистлык сәләте.

**ЖУРНА'ЛЬНЫЙ** — журнал ...-ы; *журнальная статья* — журнал мәкаләсе.

**ЖУРЧА'ТЬ** *несов.* — 1. *(о воде)* шылтырау, челтерәү, чылтырап агу; 2. *поэт.* агу; гөрләү.

**ЖУ'ТКИЙ** — 1. куркыныч, коточкыч, йөрәк яргыч, куркынычлы, хәвефле, дәһшәтле; 2.. *безл. в знач. сказ.* курку; *мне что-то жутко* — мин никтер куркам.

**ЖУ'ТКО** *нареч.* — бик, коточкыч; *жутко много народу* — коточкыч күп халык.

**ЖУ'ТКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — куркынычлылык, дәһшәтлелек, хәвефлелек.

**ЖУТЬ** *ж. мн.* нет — 1. курку, кот очу, кот чыгу; *меня жуть берёт* — мин, куркуга төшәм; 2. *в знач. сказ.* бик күп, коточкыч күп; *народу там — прямо жуть* — халык анда коточкыч күп.

**ЖУ'ХЛЫЙ** *обл. спец.* — 1. *(о краске)* тоныкланган; 2. *(о коже)* кибеп каткан.

**ЖУ'ЧИТЬ** *несов., разг. фам.* — шелтәләү, әрләү, тиргәү.

**ЖУ'ЧКА** *ж.* — сөяк калкан, саклагыч (кайбер балыкларда).

**ЖУЧО'К** *м.* — кечкенә коңгыз, вак коңгыз.

**ЖЮРИ'** *нескл. ср.* — 1. жюри (күргәзмәләрдә, конкурсларда, ярышларда премия яки бүләк билгеләүче белгеч-экспертлар төркеме); 2. *спорт.* судья (спорт ярышларында).

# З

**ЗА** I *предлог с вин. п.* — 1. артына, аръягына; *за ограду* — коймa артына; *за реку* — елга аръягына; 2. ...-га; *держаться за перила* — култыксага тотыну; *приняться за работу* — эшкә тотыну; *купить за 10 рублей* — 10 сумга сатып алу; *выйти (замуж) за кого-н.* — берәүгә кияүгә чыгу; 3. өчен; *борьба за мир* — тынычлык өчен көрәш; *сколько следует за хлеб?* — икмәк өчен күпме тиеш? *рад за вас* — сезнең өчен шатмын! *беспокоиться за детей* — балалар өчен борчылу; 4. эчендә; *много сделано за неделю* — бер атна эчендә күп эшләнгән; 5. ...-дан; *брать за руку* — кулдан тоту; 6. ...-да, ераклыкта; *жить за десять километров от города* — шәһәрдән ун километрда (ун километр ераклыкта) тору; *за версту отсюда* — моннан бер чакрымда (бер чакрым ераклыкта); 7. калгач, кала, элек, алдан; *за час до отхода поезда* — поезд китәргә бер сәгать калгач (бер сәгать кала), поезд китүдән бер сәгать элек; 8. дип, итеп; *выдать себя за инженера* — үзенне инженер итеп күрсәтү; *признать за благо* — яхшылык дип тану; 9. янына; *сесть за стол* — өстәл янына утыру. ◇ **Ей далеко за сорок** — ул күптән инде кырыктан узган. **Уже за полночь** — инде ярты төн үтеп киткән. **Ни за что** — һич тә, һичбер вакытта да. **За и против** — яклап һәм каршы; *за предложение председателя голосовали сорок человек,*

*против — пять* — председатель тәкъдимен яклап кырык кеше, каршы — биш кеше тавыш бирде. Что за — нинди; *что за человек?* — нинди кеше бу?

**ЗА** II *предлог с твор. п.* — 1. артында, аръягында; *за шкафом* — шкаф артында; *за рекой* — елга аръягында; 2. артыннан; *идти за отрядом* — отряд артыннан бару; 3. янында; *сидеть за столом* — өстәл янында утырып тору; *стоять за станком* — станок янында басып тору; 4. ...-га; *идти за водой* — суга бару; *ехать за товаром* — товарга бару; 5. ...-да; *за тобой долг* — синдә аласым бар; *задержка за деньгами* — тоткарлык акчада; 6. сәбәпле; аркасында, белән; *за молодостью* — яшьлек сәбәпле; 7. ...-да, вакытында; *за работой* — эшләгәндә, эш вакытында; 8. ...-ны; *ухаживать за больным* — авыруны карау; *следить за изменением температуры* — температура үзгәрешен күзәтеп тору. ◇ **Бумага за подписью секретаря, за печатью учреждения** — секретарьның имзасы, учреждениенең печате куелган кәгазь. **Дело за номером 10** — 10 нчы номерлы дело.

**ЗААВАНСИ'РОВАТЬ** *сов.* — аванс биреп кую, аванс рәвешендә түләү.

**ЗААЛЕ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. *(начать алеть)* аллана башлау; 2. *(показаться)* алсуланып күренү.

**ЗААЛЕ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — к. заалеть.

**ЗААПЛОДИ'РОВАТЬ** *сов.* — кул чаба башлау, алкышлый башлау.

**ЗААРЕНДОВА'ТЬ** *сов.* — арендалау, арендага алу.

**ЗААРЕНДО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. заарендовать.

**ЗААРЕСТОВА'ТЬ** *сов. простореч.* — к арестовать.

**ЗААРКА'НИТЬ** *сов. обл.* — к. арканить.

**ЗААРТА'ЧИТЬСЯ** *сов. разг.* — киреләнә башлау, карыша башлау, кәҗәләнә башлау, үҗәтләнә башлау; *(о лошади)* чыгымлый башлау, чыгымчылый башлау.

**ЗААТЛАНТИ'ЧЕСКИЙ** *книж. устар.* — Атлантик океан аръягындагы; Атлантик океан аръягыннан китерелгән.

**ЗАА'ХАТЬ** *сов. разг.* — ахылдый башлау.

**ЗАБА'ВА** *ж.* — уен, уен-көлке, күңел ачу, мәзәк, тамаша; *в клубе организовали игры и забавы для детей* — клубта балалар өчен уеннар һәм төрле тамашалар оештырдылар; *такое серьёзное дело вы не превращайте в забаву* — мондый житди эшне сез уенга әйләндермәгез.

**ЗАБАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. күңелен ачу, юату; 2. ...-дан көләсе килү; *ваши угрозы меня только забавляют* — сезнең янаулардан минем көләсем генә килә.

**ЗАБАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — юану, күңел ачу. ◇ **Котёнок забавляется** — песи баласы уйный, шаяра.

**ЗАБА'ВНИК** *м.*, **ЗАБА'ВНИЦА** *ж. разг.* — уенчак, көлдерүчән, мәзәкчән.

**ЗАБА'ВНО** — 1. *нареч.* кызык итеп, көлке итеп, күңелле итеп; *он забавно рассказывает* — ул кызык итеп сөйли; 2. *нареч.* кызык, мәзәк; *забавно было смотреть, как он сердился* — аның ачулануын карап тору кызык иде; 3. *в знач. сказ.* — кызык, көлке; *ему забавно* — аңа кызык.

**ЗАБА'ВНЫЙ** — кызык, кызыклы; *забавный ребёнок* — кызык бала; *забавный случай* — кызыклы вакыйга.

**ЗАБАЛЛОТИРОВА'ТЬ** *сов.* — сайламый калдыру (кандидатурасы куелган кешене).

**ЗАБА'ЛТЫВАТЬ** I *несов.* — к. заболтать II.

**ЗАБА'ЛТЫВАТЬ** II *несов. простореч.* — к. заболтать III 2.

**ЗАБА'ЛТЫВАТЬСЯ** I *несов. страд., разг.* — тугылану, тугылап катнаштырылу.

**ЗАБА'ЛТЫВАТЬСЯ** II *несов., разг.* — 1. лыгырдау белән мавыгу; 2. вакыт-вакыт сөйләү сәләтен югалту.

**ЗАБАРАБА'НИТЬ** *сов.* — барабан кага башлау; шакылдата башлау; *он забарабанил пальцами по столу* — ул бармаклары белән өстәлне шакылдата башлады. ◇ **Дождь забарабанил по крыше** — яңгыр түбәгә шыбыр-шыбыр ява башлады.

**ЗАБАРРИКАДИ'РОВАТЬ** *сов.* — к. баррикадировать.

**ЗАБАРРИКАДИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* — баррикадалану.

**ЗАБАСИ'ТЬ** *сов. разг.* — калын тавыш белән сөйли башлау; калын тавыш белән жырлый башлау.

**ЗАБАСТОВА'ТЬ** *сов.* — забастовка ясау, эш ташлау.

**ЗАБАСТО'ВКА** *ж.* — забастовка, эш ташлау (капиталистик илләрдә эшчеләр сыйныфының экономик яки политик таләпләр куеп һәм шул таләпләренең үтәлүенә, тормышка ашырылуына ирешү өчен, массовый төстә эш ташлавы).

**ЗАБАСТО'ВОЧНЫЙ** — забастовка ...-ы; *забастовочный комитет* — забастовка комитеты.

**ЗАБАСТО'ВЩИК** *м.*, **ЗАБАСТО'ВЩИЦА** *ж.* — забастовкачы, забастовкада катнашучы.

**ЗАБВЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. к. забыть; 2. к. забыться. ◇ **Предать забвению** *книж.* — оныту, искә алмау.

**ЗАБВЕ'ННЫЙ** *книж. устар.* — онытылган, истән чыгарылган.

**ЗАБЕ'Г** *м. спорт.* — йөгерү, узыш; *забег на четыреста метров* — дүрт йөз метрга йөгерү.

**ЗАБЕ'ГАТЬ** *сов.* — йөгерә башлау; әрлебирле йөгерә башлау. ◇ **Глаза его забегали** — аның күзләре уйный башлады.

**ЗАБЕГА'ТЬ** *несов.* — 1. кергәләү, кереп чыгу; *он часто к нам забегает* — ул безгә еш кергәли; 2. (еракка) йөгереп китү. ◇ **Забегать вперед** *перен. разг.* — вакытыннан элек эшләү. **Забегать вперед начальству** — начальство каршында ялагайлану, начальствога тәлинкә тоту.

**ЗАБЕ'ГАТЬСЯ** *сов. разг.* — йөгерә-йөгерә хәлдән таю, арып бетү.

**ЗАБЕЖА'ТЬ** *сов.* — 1. йөгереп ... чыгу; *забежать вперёд* — йөгереп алга чыгу; 2. *разг.* кереп чыгу; *забежать к знако-*

*мым* — танышларга кереп чыгу; 3. йөгереп керү; чабып керү; *забежать во двор* — ишек алдына йөгереп керү.

**ЗАБЕЛЕ'ТЬ** *сов.* — 1. *(начать белеть)* агара башлау; 2. күренә башлау (ак әйбер турында); *вдали забелели меловые горы* — еракта акбур таулары күренә башлады.

**ЗАБЕЛЕ'ТЬСЯ** *сов.* — к. забелеть.

**ЗАБЕЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(произвести побелку)* агарту, акка буяу, акшарлау; 2. *разг.* салу, кату (мәсәлән, чәйгә сөт салу, ашка катык кату).

**ЗАБЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. забелить.

**ЗАБЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — агартылу, акка буялу, акшарлану.

**ЗАБЕРЕ'МЕНЕТЬ** *сов.* — балага узу, авырга узу, корсакка узу, йөккә узу, авырга калу.

**ЗАБЕСПОКО'ИТЬСЯ** *сов.* — борчыла башлау, тынычсызлана башлау.

**ЗАБИВА'ТЬ** *несов.* — к. забить 1, 2, 3, 4, 5, 9, 10, 11.

**ЗАБИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. забиться 2, 3; 2. *страд.* кагып кертелү; томалану, каплану; кадаклап куелу; бәреп кертелү; суелу.

**ЗАБИНТОВА'ТЬ** *сов.* — бинт белән бәйләү, бәйләп кую (яраны).

**ЗАБИНТОВА'ТЬСЯ** *сов.* — бинт белән бәйләнү.

**ЗАБИНТО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. забинтовать.

**ЗАБИНТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. забинтоваться.

**ЗАБИРА'ТЬ** *несов., разг.* — к. забрать.

**ЗАБИРА'ТЬСЯ** I *несов., разг.* — 1. к. забраться; 2. *страд.* алыну; кулга алыну, арестовать ителү.

**ЗАБИРА'ТЬСЯ** II *несов., просторен.* — к. забраться II.

**ЗАБИ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — боеклык, кимсетелгәнлек, кыерсытылганлык; күңел төшенкелек.

**ЗАБИ'ТЫЙ** — 1. *(вбитый)* кагылган, кадакланган; кагып кертелгән; 2. тутырылган, тыгызлап тутырылган, дыңгычлап тутырылган; 3. капланган, томаланган (берәр нәрсә белән); 4. *(запуганный, измученный)* боек, боеккан, боектырылган, кыерсытылган, кимсетелгән.

**ЗАБИ'ТЬ** *сов.* — 1. кагып кертү; *забить гвоздь* — кадак кагып кертү; 2. томалау, каплау; *забить щели* — ярыкларны томалау; 3. *(наполнить до предела)* тутыру, тыгызлап тутыру, дыңгычлап тутыру; 4. кадаклап кую; *забить дверь* — ишекне кадаклап кую; 5. *(замучить побоями)* кыйнап эштән чыгару; 6. кага башлау; *забить в барабан* — барабан кага башлау; *петух забил крыльями* — этәч канатларын кага башлады; 7. ата башлау, ургылып чыга башлау; *из скважины нефть забила фонтаном* — скважинадан нефть фонтан булып ата башлады (ургылып чыга башлады); 8. күтәрү; *забить тревогу* — тревога күтәрү; 9. *разг.* җиңеп чыгу, өстен чыгу, уздыру; *он всех забьёт* — ул барысын да җиңеп чыгар; 10. *спорт.* бәреп (сугып, тибеп) кертү; *забить шар в угол* — шарны почмакка бәреп кертү (бильярд уенында); 11. сую; *забить десять голов овец* — ун баш сарык сую.

**ЗАБИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(начать биться)* бәреләсугыла башлау; *(о сердце)* тибә башлау; 2. посу, качу; *забиться в угол* — почмакка посу; 3. тыгылу, томалану; *труба забилась сажей* — трубага корым тыгылган.

**ЗАБИЯ'КА** *м.* и *ж. разг.* — сугыш чукмары, җәнҗалчы.

**ЗАБЛАГОВРЕ'МЕННО** *нареч., книж.* — алдан, вакытыннан элек.

**ЗАБЛАГОРАССУ'ДИТЬ** *сов. книж. устар.* — дөрес дип табу, кирәкле дип табу.

**ЗАБЛАГОРАССУ'ДИТЬСЯ: как ему заблагорассудится, так и делает** — ничек теләсә, шулай эшли; **он делает то, что ему заблагорассудится** — башына ни килсә, шуны эшли.

**ЗАБЛЕСТЕ'ТЬ** *сов.* — ялтырый башлау, ялтырап күренә башлау, җемелди башлау; *на небе заблестели звёзды* — күктә йолдызлар җемелди башлады. ◇ **На её глазах заблестели слёзы** — күзләреннән мөлдерәп яшь чыкты.

**ЗАБЛЕЯ'ТЬ** *сов.* — мәэлди башлау, кычкыра башлау (сарык турында); *во дворе заблеяли овцы* — ишек алдында сарыклар мәэлди башлады.

**ЗАБЛИСТА'ТЬ** *сов. книж.* — к. заблестеть.

**ЗАБЛУДИ'ТЬСЯ** *сов.* — адашу, юлдан язу. ◇ **Заблудиться в трёх соснах** — өч нарат арасында адашу (ачык мәсьәләдә буталып калу).

**ЗАБЛУ'ДШИЙ** *книж. устар.* — 1. адашкан, юлдан язган; 2. *(беспутный)* әхлаксыз, бозык юлга кергән, юлдан язган.

**ЗАБЛУЖДА'ТЬСЯ** *несов.* — ялгышу, ялгыш фикердә булу, ялгыш караштa булу; *ты заблуждаешься, считая это второстепенным делом* — моны икенче дәрәҗәдәге эш дип санавың белән син ялгышасың.

**ЗАБЛУЖДЕ'НИЕ** *ср. книж.* — ялгышлык, ялгыш фикер. ◇ **Ввести в заблуждение** — ялгыштыру, ялгыш юлга кертү. **Впасть в заблуждение** — ялгышу, ялгыш юлга кереп китү. **Быть, находиться в заблуждении** — ялгыш караштa булу.

**ЗАБОДА'ТЬ** *сов. разг.* — сөзү, сөзеп үтерү.

**ЗАБО'Й** *м.* — 1. *горн.* забой (шахтада күмер, руда казу урыны); 2. субайлар тезмәсе (суга утыртылган баганалар); 3. *спорт.* башлап сугу (футбол, лапта, волейбол һ. б. уеннарда); 4. *только ед. (действие)* сую, чалу; *забой скота* — терлек сую; 5. *(количество убитого скота)* суелган терлекнең саны; 6. аякны аякка бәрү (атларда чапканда була торган кимчелек).

**ЗАБО'ЙЩИК** *м. горн.* — забойщик, забойчы (шахтада эшләүче эшче).

**ЗАБОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — к. заболотиться.

**ЗАБОЛЕВА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет — авырулар саны; *снижение заболеваемости* — авырулар саны кимү.

**ЗАБОЛЕВА'НИЕ** *ср.* — 1. авырый башлау, чирли башлау; *момент заболевания* — авырый башлау моменты; 2. авыру, чир; *заразное заболевание* — йогышлы авыру.

**ЗАБОЛЕВА'ТЬ** I *несов.* — к. заболеть I.

**ЗАБОЛЕВА'ТЬ** II *несов.* — к. заболеть II.

**ЗАБОЛЕ'ТЬ** I *сов.* — авыру, авырый башлау, авырып китү, чирләү, чирли башлау, чирләп китү; *заболеть ангиной* — ангина белән авыру.

**ЗАБОЛЕ'ТЬ** II *сов.* — авырта башлау, сызлый башлау; *у меня заболела голова* — минем башым авырта башлады.

**ЗАБОЛО'ННИК** *м. зоол.* — төчлегән коңгызы (агач кайрысы ашаучы корткыч коңгыз).

**ЗАБОЛО'ННЫЙ** — төчлегән ...-ы; *заболонный слой дерева* — агачның төчлегән катлавы.

**ЗА'БОЛОНЬ** *ж. бот.* — төчлегән, төслегән (агачның кайры астындагы яшь катлавы).

**ЗАБОЛО'ТИТЬСЯ** *сов.* — сазлану, сазга әйләнү.

**ЗАБОЛТА'ТЬ** I *сов. разг.* — селки башлау, болгый башлау; *мальчик сел и заболтал ногами* — малай утырды да аякларын селки башлады.

**ЗАБОЛТА'ТЬ** II *сов. разг.* — тугылау, болгату, тугылап катнаштыру, селкетеп болгату.

**ЗАБОЛТА'ТЬ** III *сов.* — 1. лыгырдый башлау, лыкылдый башлау, такылдый башлау; 2. *простореч.* күп лыкылдап туйдырып бетерү.

**ЗАБОЛТА'ТЬСЯ** I *сов. разг.* — 1. (*о жидкости*) болгана башлау, чайкала башлау; 2. селкенә башлау; *на верёвке заболталось бельё* — бауда кер селкенә башлады.

**ЗАБОЛТА'ТЬСЯ** II *сов. разг. фам.* — озак лыгырдап тору, лыгырдау белән мавыгу.

**ЗАБО'Р** *м.* — койма.

**ЗАБО'РИСТЫЙ** *разг. фам.* — 1. көчле, зәһәр, үткен, каты; *забористый табак* — каты тәмәке; 2. *перен.* үткен, кызыклы, чәнечкеле; *забористое слово* — үткен сүз.

**ЗАБО'РНЫЙ** I — 1. койма ...-ы; *заборный столб* — койма баганасы; 2. *перен.* әдәпсез, оятсыз; *заборные слова* — әдәпсез сүзләр.

**ЗАБО'РНЫЙ** II — забор ...-ы; *заборная книжка* — забор кенәгәсе (магазиннан товар ала торган кенәгә).

**ЗАБОРОНИ'ТЬ** *сов. с.-х.* — тырмалау, тырмалап бетерү.

**ЗАБО'ТА** *ж.* — 1. кайгырту, хәстәрен күрү; *забота о будущем* — киләчәк турында кайгырту; 2 *только мн.* мәшәкатьләр; *день проходит в заботах* — көн мәшәкатьләр белән үтә; 3. *разг.* бурыч, эш; *закончить учёбу — это моя первая забота* — укуны тәгәлләү — минем беренче бурычым. ◇ **Без забот** — гамьсез, ваемсыз. **Не было заботы!** — шул гына кирәк иде! (шуны гына көтеп тора идем; шул гына житмәгән иде!). **Ему и заботы мало** *разг.* — аның исе дә китми.

**ЗАБО'ТИТЬ** *несов.* — борчу, тынычсызлау; мәшәкатьләү; *его сильно заботит болезнь ребёнка* — баласының авыруы аны бик нык борчый.

**ЗАБО'ТИТЬСЯ** *несов.* — 1. кайгыртучанлык күрсәтү; игътибар бирү; *заботиться о здоровье трудящихся* — хезмәт ияләренең сәламәтлеге турында кайгыртучанлык күрсәтү; 2. кайгырту, хәстәрен күрү; артыннан йөрү; *ему ни о чём не придётся заботиться* — аңа бернәрсә турында да кайгыртырга туры килмәячәк.

**ЗАБО'ТЛИВО** *нареч.* — тырышып, игътибар итеп, кайгыртучанлык күрсәтеп; хәстәрен күреп; *заботливо выращивать молодняк* — яшь терлекләрне тырышып тәрбияләп үстерү.

**ЗАБО'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — кайгыртучанлык.

**ЗАБО'ТЛИВЫЙ** — 1. кайгыртучан, хәстәрен күрүчән; *заботливый отец* — кайгыртучан ата; 2. тырыш, алдан кайгыртучан; *заботливый хозяин* — тырыш хужа; 3. игътибарлы; *заботливый уход* — игътибарлы тәрбия.

**ЗАБОЯ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — куркып калу, шүрләү.

**ЗАБРАКОВА'ТЬ** *сов.* — бракка чыгару, яраксызга чыгару, яраксыз табу.

**ЗАБРА'ЛО** *ср. истор.* — битлек, бит каплавычы (тимер шлемның сугыш вакытында битне каплый торган алгы өлеше). ◇ **Выступить без забрала (или с открытым забралом)** — ачыктан-ачык чыгу (үзенең теләкләрен һичбер яшермичә, турыдантуры әйтү; хәйләләп маташмыйча, туптуры әйтеп бирү).

**ЗАБРА'СЫВАТЬ** *несов.* — к. забросать и забросить.

**ЗАБРА'СЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. ыргытылу, еракка ыргытылу; салыну, еракка салыну (кармак); 2. китерелү, кайтарылу.

**ЗАБРА'ТЬ** *сов.* — 1. алу; *забрать с собой книги* — китапларны үзең белән алу; *забрать в плен* — пленга алу; *забрать в солдаты* — солдатка алу; 2. *разг. (арестовать)* кулга алу; арестовать итү, тотып алу; 3. *портн.* жыю, тарайту; *забрать шов* — жөйне тарайту; 4. каплау, кадаклап кую, томалау; *забрать окно досками* — тәрәзәне такталар белән кадаклап кую; 5. эләктерү, эләктереп алу; *винт забрал* — винт эләктереп алды. ◇ **Забрала охота (что-н. делать)** — теләк туды, ...-сы килеп китте. **Забрала зевота** — иснәтә башлады. **Забрала тоска** — кайгы басты, эч поша башлады. **Страх забрал** — курку басты. **Забрало его за живое** *разг.* — авырткан жиренә тиде (аңа бик нык тәэсир итте). **Забрать себе в голову** — башка кертеп урнаштыру (берәр фикерне). **Забрать в руки** — буйсындыру, кулга алу, үз кулына алу, үз дигәнен эшләтү.

**ЗАБРА'ТЬСЯ** I *сов.*— 1. менү, үрмәләп менү; *забраться на верхушку дерева* — агач башына менү; 2. керү; *забраться под одеяло* — юрган астына керү; *мы забрались в самую глубь леса* — без урманның эченә үк кердек.

**ЗАБРА'ТЬСЯ** II *сов. просторечь.*— 1. (*запастись чем-н.*) җыю, әзерләү, туплау, хәзерләп кую; 2. *перен.* күп эш алу; *забраться поручениями* — күп йөкләмә алу.

**ЗАБРЕДА'ТЬ** *несов.*— к. забрести.

**ЗАБРЕ'ДИТЬ** *сов.*— саташа башлау.

**ЗАБРЕ'ЗЖИТЬ** *сов.*— 1. (*об огне*) елтырап күренә башлау; 2. *безл.* яктыра башлау, таң ата башлау, таң беленә башлау; *чуть забрезжило, мы отправились в путь* — таң ата башлагач та без юлга чыктык.

**ЗАБРЕСТИ'** *сов. разг.*— 1. барып керү, адашып барып керү; 2. (*зайти мимоходом*) кереп чыгу. ◇ **Мысль забрела в голову** *разг.*— башка бер фикер килде.

**ЗАБРИВА'ТЬ** *несов. истор.*— к. забрить.

**ЗАБРИ'ТЬ** *сов. истор.*— солдатка алу.

**ЗАБРОДИ'ТЬ** I *сов. разг.*— әрле-бирле йөри башлау.

**ЗАБРОДИ'ТЬ** II *сов.*— әчи башлау, кабара башлау.

**ЗАБРОНИ'РОВА'ТЬ** *сов.*— бронь салу, беркетеп кую; *забронировать одно место в вагоне* — вагонда бер урын беркетеп кую.

**ЗАБРОНИ'РОВА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. броня белән каплану, броня белән саклану; 2. *перен. разг.* үзен хәвефсезләндерү, үзен саклау чараларын күрү.

**ЗАБРО'С: огород в забросе** — бакча ташландык хәлдә.

**ЗАБРОСА'ТЬ** *сов.*— 1. күмү, күмеп ташлау; *артистов забросали цветами* — артистларны чәчәкләргә күмделәр; 2. *перен.* яудыру; *докладчика забросали вопросами* — докладчыга сораулар яудырдылар. ◇ **Забросать грязью** — пычрак ташлау; кара ягу.

**ЗАБРО'СИТЬ** *сов.*— 1. ыргыту, еракка ыргыту; *забросить мяч в сад* — тупны бакчага ыргыту; 2. салу, еракка салу; *забросить удочку* — кармак салу; 3. *разг.* ташлау, кую; *куда-то забросил, а теперь не может найти* — каядыр ташлаган, ә хәзер инде таба алмый; 4. ташлау; *он совсем забросил хозяйство* — ул хуҗалыгын бөтенләй ташлады; *она забросила музыку* — ул музыканы ташлады; 5. *разг.* китерү, кайтару; *в тракторную бригаду забросили запасные части* — трактор бригадасына запас частьлар китерделәр. ◇ **Судьба забросила** — язмыш китереп ташлады.

**ЗАБРО'ШЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — ташландык хәлдә булу.

**ЗАБРО'ШЕННЫЙ** — 1. ташланган, еракка ташланган (ыргытылган), ташлап калдырылган; чөеп җибәрелгән; салынган (кармак), ташлап югалтылган; билгесез урынга куеп югалтылган; 2. ташландык, ташланган, караучысыз калдырылган; ташландык хәлгә китерелгән; *заброшенный сад* — ташландык бакча; 3. илтеп ташланган, китереп ташланган.

**ЗАБРЫ'ЗГАТЬ** I *сов. разг.*— чәчрәтә башлау, бөрки башлау, сиптерә башлау; *скоро забрызжет фонтан* — тиздән фонтан сиптерә башлар.

**ЗАБРЫ'ЗГАТЬ** II *сов. обл.*— чәчрәтеп пычрату, чәчрәтеп пычратып бетерү; *забрызгать стол чернилами* — кара чәчрәтеп өстәлне пычратып бетерү.

**ЗАБРЫ'ЗГИВАТЬ** *несов.*— к. забрызгать II.

**ЗАБУБЁННЫЙ** *разг.*— 1. чамасыз, чиктән тыш; 2. тәвәккәл, гаяр; *забубённая голова* — тәвәккәл кеше, гаяр кеше; 3. гамьсез, ваемсыз; *забубённая жизнь* — ваемсыз тормыш.

**ЗАБУЛДЫ'ГА** *м. разг. неодобр.*— азгын, бозык, исерекбаш.

**ЗАБУРЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. шаулый башлау, гөрелди башлау; *забурлило море* — диңгез шаулый башлады; 2. кайный башлау; *забурлила каша в котле* — казанда ботка кайный башлады.

**ЗАБУ'ХАТЬ** *сов. разг.*— гөрселди башлау, бухылдый башлау; *пушки забухали* — туплар гөрселди башлады.

**ЗАБУХА'ТЬ** *несов.*— к. забухнуть.

**ЗАБУ'ХНУТЬ** *сов.*— бүртү, күбенү.

**ЗАБУШЕВА'ТЬ** *сов.*— шаулый башлау, котыра башлау; *ветер снова забушевал* — җил тагын котыра башлады.

**ЗАБУЯ'НИТЬ** *сов. разг.*— җәнҗал чыгара башлау; тавыш куптара башлау.

**ЗАБЫВА'ТЬ** *несов.*— к. забыть.

**ЗАБЫВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. забыться; 2. зиһенсезләнү, оныту; *дед от старости стал забываться* — бабай картлыктан зиһенсезләнә башлады.

**ЗАБЫ'ВЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — онытучанлык, хәтерсезлек, истән чыгаручанлык; *по забывчивости* — хәтерсезлек сәбәпле.

**ЗАБЫ'ВЧИВЫЙ** — онытучан, тиз онытучан, хәтерсез.

**ЗАБЫ'ТЬ** *сов.*— 1. оныту, истән чыгару, хәтердән чыгару; 2. (*оставить по забывчивости*) онытып калдыру, оныту. ◇ **Что я там забыл?** — анда минем нәрсәм калган?

**ЗАБЫТЬЁ** *ср. мн.* нет — 1. (*беспамятство*) аңны югалту, һуштан язу; 2. (*дремота*) йокымсырап тору, йокымсырап китү.

**ЗАБЫ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (*задремать*) йокы басу, йокымсырап китү; 2. (*впасть в беспамятство*) аңны югалту, һуштан язу; 3. *книж.* (*замечтаться*) уйга чуму, уйга бату; 4. дөньяны онытып тору, онытылып тору; *он отправился на охоту, чтобы немного забыться* — бераз онытылып тору өчен ул ауга китте; 5. үзен-үзе оныту, онытылу, арттырып җибәрү; *вы забылись, так нельзя говорить* — сез арттырып җибәрдегез, алай дип сөйләргә ярамый; 6. *страд.* истән чыгарылу, хәтердән чыгарылу, онытылу; *славные подвиги наших*

*доблестных воинов никогда нами не забудутся* — безнең сугышчыларның данлы батырлыклары беркайчан да онытылмаячак.

**ЗАВА'ЖНИЧАТЬ** *сов.*— эреләнә башлау, тәкәбберләнә башлау; эреләнеп китү, тәкәбберләнеп китү.

**ЗАВА'Л** *м.*— өем, тыгылу, бикләнү, томалану; *снежные завалы* — кар өемнәре; *завал в кишках* — эчәкләрнең тыгылуы.

**ЗАВА'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. завалить.

**ЗАВА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. завалиться; 2. *страд.* тутырылу, күмелү; янтайтылу; авыштырылу; аударылу.

**ЗАВА'ЛИНКА** *ж.*— нигез (өй тирәсенә өелгән туфрак).

**ЗАВАЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. тутыру, күмү; *завалить яму* — чокырны күмү (тутыру); 2. ишелеп төшеп каплау; *дорогу завалило обвалом* — тау ишелеп юлны каплаган; 3. тутыру; *завалить улицу брёвнами* — урамны бүрәнәләр белән тутыру; 4. *перен.* күмү, күп эш йөкләү; *его завалили работой* — аңа бик күп эш йөкләделәр; 5. янтайту; *завалить шкаф к стене* — шкафны стенага таба янтайту; 6. җимерү, аудару; *завалить стену* — стенаны җимерү; 7. *безл. простореч.* тыгылу; *завалило уши* — колаклар тыгылды; 8. *перен. просторен.* җимерү, харап итү; *завалить дело* — эшне харап итү.

**ЗАВАЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. төшү, төшеп китү; *книга завалилась за полку* — китап шүрлек артына төшеп китте; 2. яту, аву; *он завалился на диван* — ул диванга ауды (ятты); 3. кырынаю, кыйшаю; янтаю; *забор завалился* — койма кыйшайды; 4. (*упасть, обрушиться*) җимерелеп төшү, ишелеп төшү.

**ЗА'ВАЛЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— 1. *собир.* яткан товар, начар товар; 2. *перен.* юк-бар нәрсә, чүп-чар.

**ЗАВАЛЯ'ТЬ** *сов. просторен.*— 1. аунata башлау; тәгәрәтә башлау; әвәли башлау; 2. (*затаскать, загрязнить*) аунатып бетерү, пычратып бетерү, таушалдырып бетерү.

**ЗАВАЛЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. озак яту; *заявление завалялось у секретаря* — гариза секретарьда озак яткан; 2. (*остаться непроданным*) сатылмый калу (товар турында).

**ЗАВАЛЯ'ЩИЙ** *разг.*— начар, начар сыйфатлы, түбән бәяле, яраксыз.

**ЗАВА'РИВАТЬ** *несов.*— к. заварить.

**ЗАВА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. завариться; 2. *страд.* (*о чае*) пешерелү, салыну; 3. (*обдаваться кипятком*) пешекләнү.

**ЗАВАРИ'ТЬ** *сов.*— 1. салу, пешерү; *заварить чай* — чәй салу (пешерү); 2. (*обдать кипятком*) пешекләү. ◇ **Заварить дело, заварить кашу** *перен.*— мәшәкатьле (күңелсез) эш башлап җибәрү.

**ЗАВАРИ'ТЬСЯ** *сов.*— пешү, пешеп җитү; *чай заварился* — чәй пеште. ◇ **Дело заварилось, каша заварилась** *перен.*— мәшәкатьле (күңелсез) эш башланып китте.

**ЗАВАРНО'Й** — 1. пешекләү ...-ы; пешерү ...-ы; *заварной котёл* — пешекләү казаны; 2. заварной, кайнар суга басып куелган; *заварное тесто* — кайнар суга басып куелган камыр.

**ЗАВАРУ'ХА** *ж.*— к. завороха.

**ЗАВЕДЕ'НИЕ** *ср.*— заведение, учреждение, предприятие; йорт; *учебные заведения* — уку йортлары. ◇ **Такое (или таково) заведение** *просторен.*— шундый йола инде, шундый гадәт инде.

**ЗАВЕ'ДОВАТЬ** *несов.*— идарә итү; *заведовать детсадом* — балалар бакчасы белән идарә итү.

**ЗАВЕ'ДОМО** *нареч.*— күрә торып, белә торып, күрәләтә.

**ЗАВЕ'ДОМЫЙ** — билгеле, һәркемгә билгеле, ап-ачык, чеп-чи, күренеп тора торган; *заведомый лентяй* — һәркемгә билгеле ялкау; *заведомая ложь* — чеп-чи ялган.

**ЗАВЕ'ДУЮЩИЙ** *в знач. сущ.*— мөдир, заведующий.

**ЗАВЕ'ДЫВАТЬ** *несов., канц. устар.*— к. заведовать.

**ЗАВЕЗТИ'** *сов.*— 1. кертеп чыгу (ат белән яки машина белән); *завезти письмо* — хат кертеп чыгу; 2. илтеп ташлау; *завезти в глушь* — караңгы почмакка илтеп ташлау; 3. *торг.* китерү, кайтару; *завезти товары в магазин* — магазинга товарлар китерү.

**ЗАВЕРБОВА'ТЬ** *сов.*— к. вербовать 1.

**ЗАВЕРЕ'НИЕ** *ср.*— 1. (*уверение*) ышандыру; 2. раслау, раслату; *заверение подписи* — имзаны раслату.

**ЗАВЕРИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ЗАВЕРИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. офиц.*— раслаучы, таныклаучы; *на этом документе есть подписи двух заверителей* — бу документка ике раслаучы кул куйган.

**ЗАВЕ'РИТЬ** *сов.*— 1. (*уверить*) ышандыру; 2. раслау, таныклау; *заверить подпись* — имзаны раслау.

**ЗАВЕРНУ'ТЬ** *сов.*— 1. төрү, урау, чорнау; *завернуть ребёнка* — баланы төрү; 2. борып кую; *завернуть гайку* — гайканы борып кую; *завернуть кран* — кранны борып кую; 3. кайтару, кайтарып кую; *завернуть рукава* — җиңнәрне кайтару; *завернуть полу пальто* — пальтоның чабуын кайтару (кайтарып кую); 4. борылу, борылып керү; *автомобиль завернул направо* —автомобиль уңга борылды; 5. *разг.* (*зайти мимоходом*) сугылу, кереп чыгу; 6. *просторен.* урынлы әйтү, тапкыр әйтү; *завернуть слово* — урынлы сүз әйтү; 7. *просторен. фам.* (*сказать что-н. непристойное*) әйтеп салу.

**ЗАВЕРНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. төренү, бөркәнү, урану; *завернуться в одеяло* — одеялга төренү; 2. *просторен.* кайтарылу; *завернулась пола пальто* — пальтоның итәге кайтарылган.

**ЗАВЕРТЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. болгый башлау, әйләндерә башлау; *ямщик завертел кнутом* — ямщик чыбыркысын болгый

башлады; 2. *фам.* (*увлечь*) башын әйләндерү, башын-күзен әйләндерү.

**ЗАВЕРТЕ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. әйләнә башлау; *колесо завертелось* — тәгәрмәч әйләнә башлады; 2. *перен. разг.* җәфаланып бетү, интегеп бетү, эштән чыгу; *завертелся я с этими делами* — бу эшләр белән мин интегеп беттем; 3. *простореч.* бозылып бетү, эштән чыгу; *он совсем завертелся* — ул бөтенләй эштән чыкты.

**ЗАВЁРТКА** *ж.*— 1. к. завернуть; 2. *простореч.* төргәк; *завёртка прорвалась, и посыпалась крупа* — төргәк ертылды да ярма чәчелеп китте; 3. *простореч. обл.* (*портянка*) чолгау, чолгавыч, аякчу.

**ЗАВЁРТЫВАТЬ** *несов.*— к. завернуть.

**ЗАВЁРТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. завернуться; 2. *страд.* төрелү, уралу, чорналу; борылу, борып кертелү, борып куелу; кайтарылу.

**ЗАВЕРША'ТЬ** *несов.* — к. завершить.

**ЗАВЕРША'ТЬСЯ** *несов.*— 1. завершиться; 2. *страд.* тәгәлләнү, тәмамлану, очлану, бетерелү.

**ЗАВЕРША'ЮЩИЙ** — тәгәлләүче, тәмамлаучы, соңгы, актык: *1950 год — завершающий год послевоенной пятилетки* — 1950 ел — сугыштан соңгы бишьеллыкның актык елы.

**ЗАВЕРШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. завершить и завершиться. ◇ **В завершение (всего)** *книж.*— нәтиҗәдә, ахырда, өстәвенә, нәтиҗә итеп, йомгак итеп.

**ЗАВЕРШИ'ТЕЛЬ** *м. книж.*— тәмамлаучы, тәгәлләүче.

**ЗАВЕРШИ'ТЬ** *сов.*— тәмамлау, тәмам итү, тәгәлләү, очлау; *завершить пятилетку досрочно* — бишьеллыкны срогыннан элек тәгәлләү.

**ЗАВЕРШИ'ТЬСЯ** *сов.*— тәгәлләнү, тәмамлану, очлану, бетү; *год завершился новыми производственными успехами* — ел производствода яңа казанышлар белән тәгәлләнде.

**ЗАВЕРЯ'ТЬ** *несов.*— к. заверить.

**ЗАВЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— раслану; *справка заверяется в секретариате* — белешмә секретариатта раслана.

**ЗАВЕ'СА** *ж.*— чаршау, пәрдә. ◇ **Упала (или спала с глаз) завеса** *книж.*— мәсьәлә ачыкланды. **Приподнять завесу** *книж.*— ачыкландыру. **Дымовая завеса** *воен.*— 1. төтен пәрдә (сугыш участогын дошман күзеннән каплау өчен җибәрелгән төтен полосасы); 2. күз буяу өчен эшләнгән эш.

**ЗАВЕ'СИТЬ** *сов.*— пәрдә кору, пәрдә (чаршау) корып кую.

**ЗАВЕ'СИТЬСЯ** *сов.*— каплану (пәрдә, чаршау һ. б. белән).

**ЗАВЕ'СКА** *ж.*— күгән.

**ЗАВЕСТИ'** *сов.*— 1. алып керү, илтеп ташлау; *завести далеко* — еракка илтеп ташлау; *завести в болото* — сазлыкка алып керү; 2. *разг.* кертеп калдыру; кертеп кую, кертеп чыгу; *завести детей в школу* — балаларны мәктәпкә кертеп калдыру; 3. кору, булдыру, корып җибәрү, салу; *завести в колхозе клуб* — колхозда клуб булдыру; 4. алу, булдыру; *завести кроликов* — йорт куяннары алу; 5. урнаштыру, кертү; *завести новые порядки* — яңа тәртипләр кертү; 6. башлап җибәрү; *завести разговор* — сүз башлап җибәрү; 7. бору, җибәрү, борып җибәрү; *завести часы* — сәгатьне борып җибәрү; *завести мотор* — моторны җибәрү (эшләтә башлау). ◇ **Завести глаза** *разг.* — 1. күзләрне акайту; 2. йокыга китә башлау.

**ЗАВЕСТИ'СЬ** *сов.*— 1. була башлау, үрчи башлау; *в сарае завелись мыши* — сарайда тычканнар үрчи башлаган; 2. керү, урнашу; *завелись новые порядки* — яңа тәртипләр урнашты; 3. (*о часах, моторе и т. п.*) йөри башлау, эшли башлау; *часы завелись* — сәгать йөри башлады; *мотор завелся* — мотор эшли башлады.

**ЗАВЕ'Т** *м. книж.*— васыять; *заветы Ильича* — Ильич васыятьләре.

**ЗАВЕ'ТНЫЙ** *книж.*— 1. кадерле, изге; *заветные мечты* — кадерле хыяллар; 2. яшерен, серле; *заветный разговор* — яшерен әңгәмә; 3. *устар.* мирас булып калган; *дедушкино заветное кресло* — бабайдан мирас булып калган кресло; 4. *устар.* (*запретный*) тыелулы, тыелган.

**ЗАВЕ'ТРЕННЫЙ** *мор.*— җилгә аркан, ышык; *заветренная сторона* — җилгә аркан як, ышык як.

**ЗАВЕЧЕРЕ'ТЬ** *сов. обл.*— кич җитү, караңгы төшү.

**ЗАВЕ'ШАТЬ** *сов. разг.*— элеп тутыру, элеп каплау; *завешать стены картинами* — стеналарга картиналар элеп тутыру.

**ЗАВЕ'ШИВАТЬ** *несов.*— к. завесить и завешать.

**ЗАВЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. завеситься; 2. *страд.* корылу, пәрдә корылу.

**ЗАВЕЩА'НИЕ** *ср.* — васыять; васыять язуы, васыятьнамә.

**ЗАВЕЩА'ТЕЛЬ** *м.*, **ЗАВЕЩА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. юр.* — васыять итүче, васыять әйтеп калдыручы.

**ЗАВЕЩА'ТЕЛЬНЫЙ** — васыять ...-ы; *завещательное условие* — васыять шарты.

**ЗАВЕЩА'ТЬ** *сов.* и *несов.*, *книж.*— 1. васыять итү; 2. әйтеп калдыру, васыять итү; *Ленин завещал нам хранить и укреплять диктатуру пролетариата* — Ленин безгә пролетариат диктатурасын сакларга һәм ныгытырга васыять итте.

**ЗАВЕЩА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.*, *страд. книж.*— васыять ителү.

**ЗАВЕ'ЯТЬ** *сов.*— 1. исә башлау, өрә башлау; *завеял ветерок* — җил исә башлады; 2. каплау, күмү; *метель завеяла дорогу* — буран юлны күмгән (каплаган).

**ЗАВЗЯ'ТЫЙ** *разг.*— бик хирес, мавыккан, үтә бирелгән, башы белән чумган, дөньясын оныткан; *завзятый охотник* — бик хирес аучы.

**ЗАВИВА'ТЬ** *несов.*— к. завить.

**ЗАВИВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. завиться; 2. *страд.* бөдрәләндерелү, көдрәләндерелү.

**ЗАВИ'ВКА** *ж.*— 1. к. завить 1; 2. завивка; *шестимесячная завивка* — алты айлык завивка.

**ЗАВИ'ДЕТЬ** *сов. разг.*— ерактан күрү, күреп алу.

**ЗАВИ'ДКИ**: **завидки берут** *простореч.*— көнләшә.

**ЗАВИДНЕ'ТЬСЯ** *сов.* — күренә башлау, ерактан күренә башлау.

**ЗАВИ'ДНО** — 1. *нареч.* сокланырлык, кызыгырлык; *он завидно здоров* — ул сокланырлык (рәвештә) таза; 2. *безл. в знач. сказ.* көнчелек килү, көнләшү; *ему завидно* — аның көнчелеге килә, ул көнләшә.

**ЗАВИ'ДНЫЙ** — сокланырлык, кызыгырлык; *завидное положение* — кызыгырлык хәл.

**ЗАВИ'ДОВАТЬ** *несов.* — көнчелек килү, көнләшү, кызыгу.

**ЗАВИДУ'ЩИЙ** *простореч.* — комсыз, көнче.

**ЗАВИЗЖА'ТЬ** *сов.* — чыелдый башлау, шыңшый башлау; *собака завизжала* — эт чыелдый башлады.

**ЗАВИЛЯ'ТЬ** *сов.* — 1. болгый башлау; *собака завиляла хвостом* — эт койрыгын болгый башлады; 2. *перен.* икейөзлеләнә башлау, койрык болгый башлау.

**ЗАВИНТИ'ТЬ** *сов.*— борып кую; *завинтить гайку* — гайканы борып кую.

**ЗАВИНТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — борылып житү; *гайка хорошо завинтилась* — гайка яхшы борылып житте.

**ЗАВИ'НЧИВАТЬ** *несов.*— к. завинтить.

**ЗАВИ'НЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. завинтиться; 2. *страд.* борып куелу.

**ЗАВИРА'ЛЬНЫЙ** *разг. устар.*— ялган, буш, уйдырма; *завиральные идеи*— ялган идеяләр.

**ЗАВИРА'ТЬСЯ** *несов.*— к. завраться.

**ЗАВИРУ'ХА** I *ж. обл.*— 1. буран, күз ачмаслык буран; 2. *перен.* кыенлык, читенлек, буталчык эш.

**ЗАВИРУ'ХА** II *м.* и *ж. обл.*— үтә ялганчы, ялган капчыгы.

**ЗАВИ'СЕТЬ** *несов.*— бәйләнешле булу, бәйләнгән булу, буйсынган булу; *успех дела зависит от нас самих* — эшнең уңышлы чыгуы безнең үзебезгә бәйләнгән. ◇ **Он сделал всё, что от него зависело**— кулыннан килгәннең бөтенесен дә эшләде.

**ЗАВИ'СИМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. бәйлелек, бәйле булу; *экономическая зависимость* — экономик бәйлелек; 2. бәйләнгән булу; *зависимость цены товара от его качества* — товар бәясенең сыйфатына бәйләнгән булуы. ◇ **В зависимости от ...** — ...-нең торышына карап; *в зависимости от реальных условий* — реаль шартларның торышына карап.

**ЗАВИ'СИМЫЙ** — бәйле, ирексез, буйсынган; *зависимый человек* — буйсынган кеше; *зависимые страны* — бәйле илләр.

**ЗАВИ'СТЛИВО** *нареч.*— көнләшеп, кызыгып; *завистливо смотреть* — көнләшеп карау.

**ЗАВИ'СТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — көнләшүчәнлек, көнләүчәнлек, кызыгучанлык.

**ЗАВИ'СТЛИВЫЙ** — 1. көнче, көнләшүчән; *завистливый человек* — көнче кеше; 2. *обл.* комсыз; *завистливый на еду* — ашауга комсыз.

**ЗАВИ'СТНИК** *м.*, **ЗАВИ'СТНИЦА** *ж.*— көнче.

**ЗА'ВИСТЬ** *ж. мн.* нет — көнчелек.

**ЗАВИ'СЯЩИЙ** — кулдан килгән; *приму все зависящие от меня меры* — кулдан килгән бөтен чараларны күрермен.

**ЗАВИТО'Й** — бөдрәләнгән, бөдрәләндерелгән, көдрәләнгән, көдрәләндерелгән.

**ЗАВИТО'К** *м.*— 1. *(локон)* бөтеркә; 2. *(у растений)* үрмә, уралчык; 3. *архит.* бөтеркә бизәк. ◇ **Писать с завитками** — бормалы-сырмалы итеп язу, бормалап язу.

**ЗАВИТУ'ШКА** *ж. разг.*— к. завиток 1.

**ЗАВИ'ТЫЙ** — к. завитой.

**ЗАВИ'ТЬ** *сов.*— 1. бөдрәләү, көдрәләү; *завить волосы* — чәчне бөдрәләү; 2. үрү; *завить косу* — чәч үрү. ◇ **Завить горе верёвочкой** *простореч.* — кайгырудан туктау, кайгырмый башлау.

**ЗАВИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. *(стать вьющимся)* бөдрәләнү, көдрәләнү; 2. *(у парикмахера)* бөдрәләтү, көдрәләтү.

**ЗАВИХРЕ'НИЕ** *ср.* — бөтерелү, өерелү (һава, су турында).

**ЗАВЛАДЕВА'ТЬ** *несов.*— к. завладеть.

**ЗАВЛАДЕ'ТЬ** *сов.*— 1. алу, кулга алу, кулга төшерү; *завладеть имуществом* — мөлкәтне кулга алу; 2. *перен.* үзенә карату, үзенә тарту, үзенә ияртү; үзенә буйсындыру, үз ягына аудару; *завладеть вниманием слушателей* — тыңлаучыларның дикъкатен үзенә тарту.

**ЗАВЛЕКА'ТЕЛЬНЫЙ** *разг.*—кызыклы, күңелле; *завлекательная книга* — кызыклы китап.

**ЗАВЛЕКА'ТЬ** *несов.*— к. завлечь.

**ЗАВЛЕКА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *устар. обл.* к. завлечься; 2. *страд.* кызыктырылу.

**ЗАВЛЕ'ЧЬ** *сов.*—1. кызыктыру, кызыктырып үзенә карату, кызыктырып үз ягына аудару, кызыктырып үзенә тарту; *завлечь щедрыми обещаниями* — күп вәгъдәләр белән кызыктыру; 2. алып керү; алып китү; *жажда мести завлекла его слишком далеко* — үч алу теләге аны бик ерак алып керде.

**ЗАВЛЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — 1. мавыгу, кызыгу; 2. *(влюбиться)* гашыйк булу.

**ЗАВО'Д** I *м.*— завод; *мыловаренный завод* — сабын заводы; *конный завод* — ат заводы (нәселле атлар үрчетү предприятиесе).

**ЗАВО'Д** II *м.*— 1. жибәрү, корып жибәрү; борып жибәрү; *для завода стенных часов пришлось позвать мастера* — стена сәгатен борып жибәрү өчен мастер чакырырга туры килде; 2. кору механизмы, бору механизмы; *у часов испортился завод*—

сәгатьнең бору механизмы бозылган; 3. *тип.* завод (бер набордан басылган тиражның бер өлеше, мәсәлән, беренче завод ун мең, икенче завод 5 мең). ◇ (И) **в заводе нет** *разг.* — булганы да юк, гомергә дә булганы юк; *тараканов у нас и в заводе нет* — тараканнарның бездә булганы да юк.

**ЗАВОДИ'ЛОВКА** *ж. простореч.* — 1. тәртип бозу, кагыйдә бозу; 2. башлап җибәрүче, утаман.

**ЗАВОДИ'ТЬ** I *несов.* — к. завести.

**ЗАВОДИ'ТЬ** II *сов. простореч.* — үзе белән йөртеп алҗытып бетерү, арытып бетерү.

**ЗАВОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. завестись; 2. *страд.* корылу, булдырылу, салыну; урнаштырылу, кертелү; башлап җибәрелү; җибәрелү, борып җибәрелү.

**ЗАВОДНЕ'НИЕ** *ср.* — сuландыру; *законтурное заводнение* — тирәли сuландыру.

**ЗАВОДНО'Й** — корып (борып) җибәрелә торган, корып хәрәкәткә китерелә торган; *заводная игрушка* — корып җибәрелә торган уенчык.

**ЗАВО'ДСКИЙ, ЗАВОДСКО'Й** — 1. завод ...-ы; *заводский двор* — завод ишек алды; 2. *в знач. сущ.* завод эшчесе, заводта эшләүче.

**ЗАВО'ДЧИК** I *м. устар.* — завод хуҗасы.

**ЗАВО'ДЧИК** II *м. разг. устар.* — башлап җибәрүче, уен башлыгы, котыртучы; *заводчик всему делу* — бөтен эшне башлап җибәрүче.

**ЗАВО'ДЧИК** III *м.* — нәсел айгыры, нәсел үрчеткеч айгыр (ат заводларында).

**ЗАВО'ДЧИНА** *ж. мн.* нет, *простореч. устар.* — завод эшчеләре, заводта эшләүчеләр.

**ЗАВО'ДЧИЦА** I *ж.* — к. заводчик I.

**ЗАВО'ДЧИЦА** II *ж. разг. устар.* — к. заводчик II.

**ЗА'ВОДЬ** *ж.* — кечкенә култык, затон (агым суда яки күлләрдә).

**ЗАВОЕВА'НИЕ** *ср. книж.* — 1. (*действие*) к. завоевать; 2. яулап (сугышып) алынган территория (җир); 3. *перен. книж.* казаныш, уныш; *завоевания науки* — фән казанышлары; *великие завоевания Октября* — Октябрьның бөек казанышлары.

**ЗАВОЕВА'ТЕЛЬ** *м.*, **ЗАВОЕВА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — яулап алучы; сугышып алучы.

**ЗАВОЕВА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — яулап алу ...-ы; *завоевательные планы империалистов* — империалистларның яулап алу планнары.

**ЗАВОЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. яулап алу, сугышып алу; 2. *перен.* яулап алу, казану, ирешү; *завоевать свободу* — азатлык яулап алу; *завоевать победу* — җиңүгә ирешү; 3. *перен.* үзенә карату, буйсындыру; *он завоевал меня с первой встречи* — ул мине беренче очрашуда ук үзенә каратты; 4. *редко* сугыша башлау, сугыш ачып җибәрү.

**ЗАВОЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. завоевать 1, 2, 3.

**ЗАВО'З** *м. мн.* нет — 1. китерү, кайтару; *завоз горючего* — ягулык китерү; 2. *торг. экон.* китерелгән товарлар; *ассортимент районного завоза* — районга китерелгән товарлар ассортименты.

**ЗАВОЗИ'ТЬ** I *несов.* — к. завезти.

**ЗАВОЗИ'ТЬ** II *сов., разг., фам.* — 1. (*начать двигать чем-н.*) арлы-бирле йөртә башлау; 2. *простореч.* (*загрязнить*) аунатып бетерү, пычратып бетерү.

**ЗАВОЗИ'ТЬСЯ** I *несов. страд.* — 1. (*быть отвезённым далеко*) илтеп ташлану; 2. (*быть доставленным*) китерелү, кайтарылу.

**ЗАВОЗИ'ТЬСЯ** II *сов.* — кайнаша башлау; *под полом мыши завозились* — идән астында тычканнар кайнаша башлады.

**ЗАВО'ЗНЫЙ** — читтән китерелгән, читтән кертелгән.

**ЗАВО'ЗЧИК** *м.* — товар китерүче, товар кайтаручы.

**ЗАВОЛА'КИВАТЬ** *несов.* — к. заволочь.

**ЗАВОЛА'КИВАТЬСЯ** *несов.* — к. заволочься.

**ЗАВО'ЛЖСКИЙ** — Волганың сул ягындагы (урта һәм түбән агымында); *орошение заволжских земель* — Волганың сул ягындагы җирләрне сугару.

**ЗАВОЛНОВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*о море*) дулкынлана башлау; 2. (*забеспокоиться*) борчыла башлау, тынычсызлана башлау.

**ЗАВО'ЛЖЬЕ** *ср.* — Волганың сул ягы, Иделнең сул ягы (Волганың урта һәм түбән агымының сул ягындагы районнарга карата әйтелә).

**ЗАВОЛО'ЧЬ** *сов.* — 1. каплау, каплап алу; *тучи заволокли небо* — болытлар күк йөзен каплап алды; 2. *простореч. обл.* өстерәп (сөйрәп) кертү; тартып кертү; *я заволок сани в сарай* — чананы сарайга тартып керттем.

**ЗАВОЛО'ЧЬСЯ** *сов.* — каплану, томалану; *небо заволоклось тучами* — күк йөзе болытлар белән капланды.

**ЗАВОНЯ'ТЬ** *сов. разг.* — ис килә башлау, сасы ис килә башлау.

**ЗАВОПИ'ТЬ** *сов. разг.* — акырып җибәрү.

**ЗАВОРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. заворожить 1, 2.

**ЗАВОРА'ЧИВАТЬ** I *несов.* — к. завернуть.

**ЗАВОРА'ЧИВАТЬ** II *несов.* — к. заворотить.

**ЗАВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. заворотиться; 2. кайтарылу, сызганылу; *рукава заворачиваются до локтя* — җиң терсәккә кадәр кайтарыла.

**ЗАВОРКОВА'ТЬ** *сов.* — гөрли башлау; *голуби заворковали* — күгәрченнәр гөрли башлады.

**ЗАВОРОЖИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. *поэт. устар., обл.* (*заколдовать*) сихерләү; 2. *перен. книж.* (*очаровать*) үзенә карату, сөйдерү, сихерләү; 3. (*начать ворожить*) багучылык итә башлау, күрәзәлек итә башлау.

**ЗА'ВОРОТ** *м. мед.* — борылу, уралу, кайтарылу; *заворот кишок* — эчәкләр уралу (чуалу); *заворот век* — күз кабаклары кайтарылу.

**ЗАВОРО'Т** *м. мн.* нет, *обл.*— борылыш; *я его встретил на завороте дороги*— мин аны юл борылышында очраттым.

**ЗАВОРОТИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. бору, борылу; *как проедешь мост, завороти направо* — күперне чыккач та уңга борыл; *завороти назад* — кирегә бор; *заворотили в переулок* — тыкрыкка борылдылар; **2.** кайтару; *заворотить рукава* — җиңнәрне кайтару.

**ЗАВОРОТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— кайтарылу.

**ЗАВОРО'ХА, ЗАВОРО'ШКА** *ж. простореч. обл.*— буталчыклык, ыгы-зыгы.

**ЗАВОРО'ЧАТЬ** *сов. разг.*— 1. *(начать ворочать)* әйләндерә башлау, тәгәрәтә башлау; **2.** *перен.* йөртә башлау; *приехал и заворочал всеми делами* — килү белән бөтен эшне йөртә башлады (бөтен эшне үз кулына алды).

**ЗАВОРО'ЧАТЬСЯ** *сов. разг.*— әйләнгәли башлау; *мой сосед заворочался на кровати* — минем күрше кроватьта әйләнгәли башлады.

**ЗАВОРОШИ'ТЬ** *сов.*— 1. кабарта башлау; *заворошить сено* — печәнне кабарта башлау; **2.** болгата башлау; *заворошить печь* — мичне болгата башлау.

**ЗАВОРОШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— кыймылдый башлау; мыж килә башлау.

**ЗАВРАЖДОВА'ТЬ** *сов. книж.* — дошманлаша башлау.

**ЗАВРА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— чамадан тыш ялганлау; үтә ялганчылыкка сабышу.

**ЗАВСЕГДА'** *нареч. простореч.* — к. всегда.

**ЗАВСЕГДА'ТАЙ** *м. разг.*— һәрвакыт булучы (кеше), һәрвакыт йөрүче (кеше); *завсегдатай театра* — һәрвакыт театрда булучы.

**ЗА'ВТРА** *нареч.*— иртәгә. ◇ **Не нынче-завтра** *разг.*— бүген-иртәгә, тиздән.

**ЗА'ВТРАК** *м.* — иртәнге аш, завтрак. ◇ **Кормить завтраками** *разг. фам.*— иртәгә-иртәгә дип алдап йөртү.

**ЗА'ВТРАКАТЬ** *несов.*— иртәнге аш ашау, завтрак ашау.

**ЗА'ВТРАШНИЙ** — иртәгәге, иртәгесе; *на завтрашний день* — иртәгәге көнгә; *с завтрашнего дня* — иртәгесе көннән.

**ЗАВУАЛИ'РОВАТЬ** *сов. книж.*— томалап кую, каплап кую, каплау (мәсәлән, берәр кимчелекне).

**ЗАВШИ'ВЕТЬ** *сов. простореч.*— бетләү, бетләп бетү.

**ЗАВЫВА'ТЬ** *несов.*— улау; *ветер завывает* — җил улый.

**ЗАВЫ'СИТЬ** *сов. разг.*— чамадан тыш күтәрү, арттыру; артык күтәрү; *завысить расценки* — бәяләрне артык күтәрү.

**ЗАВЫ'ТЬ** *сов.* — улый башлау; *завыла собака* — эт улый башлады.

**ЗАВЫША'ТЬ** *несов.*— к. завысить.

**ЗАВЯДА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. завянуть.

**ЗАВЯЗА'ТЬ** I *сов.* — 1. бәйләү; *завязать галстук* — галстук бәйләү; **2.** *перен.* башлау, керешү, башлап җибәрү; *завязать разговор* — сөйләшә башлау, сүзгә керешү. ◇ **Завязать узел**—төен төйнәү.

**ЗАВЯЗА'ТЬ** II *несов.*— к. завязнуть.

**ЗАВЯЗА'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** бәйләнү; **2.** *перен.* башлану, башланып китү; *завязался бой* — сугыш башланып китте; *беседа завязалась*— беседа башланып китте; **3** *бот.* төймәләнү; *плод завязался* — җимеш төймәләнде.

**ЗАВЯЗИ'ТЬ** *сов. разг.*— батыру; *завязить ногу в глине* — аякны сутлы балчыкка батыру.

**ЗАВЯ'ЗКА** *ж.*— 1. *разг.* к. завязать I в 1 зн.; 2. ялау, бәйләвеч; *халат с завязками* — ялаулы халат; **3.** *только ед. перен.* башланыш, башланып китү; *завязка боя*— сугышның башланып китүе; *завязка событий в драме* — драмада вакыйгаларның башланып китүе.

**ЗАВЯ'ЗНУТЬ** *сов.*— 1. бату, батып калу; *завязнуть в болоте* — сазлыкка бату; **2.** *перен.* бату, чуму; *завязнуть в долгах* — бурычка бату; **3.** кысылу; *завязнуть в зубах*— теш арасына кысылу.

**ЗАВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. завязать I.

**ЗАВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. завязаться

**ЗА'ВЯЗЬ** *ж. бот.*— җимшән, җимешлек (чәчәкнең җимеш барлыкка килә торган өлеше); *завязь верхняя* — өске җимшән; *завязь нижняя* — аскы җимшән.

**ЗАВЯ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. завялить.

**ЗАВЯ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*—1.к. завялиться; 2. *страд.* какландырылу, киптерелү.

**ЗАВЯ'ЛИТЬ** *сов.*— каклау, киптерү; *завялить рыбу* — балык(ны) каклау.

**ЗАВЯ'ЛИТЬСЯ** *сов.*— каклану, кибү.

**ЗАВЯ'ЛЫЙ** *обл.*— шиңгән, корыган, сулган, пәжегән.

**ЗАВЯ'НУТЬ** *сов.*— шиңү, шиңеп бетү, кору, корып бетү, сулу, сулып бетү, пәҗү, пәҗеп бетү.

**ЗАГАДА'ТЬ** *сов.*— 1. әйтү; *загадать загадку* — табышмак әйтү; 2. уйлау; *загадайте какое-нибудь число* — нинди дә булса сан уйлагыз; **3.** *(предположить)* гөман итү, алдан уйлап кую; 4. *(начать гадать)* багучылык итә башлау, фал ача башлау.

**ЗАГА'ДИТЬ** *сов. разг.*-- пычрату, пычратып бетерү, шакшылау, шакшылап бетерү.

**ЗАГА'ДКА** *ж.*— 1. табышмак; **2.** сер, башваткыч; *загадки природы* — табигать серләре. ◇ **Говорить загадками** — кинаяләп сөйләү, читләтеп сөйләү.

**ЗАГА'ДОЧНО** *нареч.*— серле, серле итеп, аңламаслык итеп; *вести себя загадочно* — үзен серле тоту.

**ЗАГА'ДОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — серлелек, билгесезлек, аңлаешсызлык.

**ЗАГА'ДОЧНЫЙ** — серле, аңлаешсыз, билгесез; *загадочное явление* — серле күренеш.

**ЗАГА'ДЫВАТЬ** *несов.*— к. загадать 1, 2, 3.

**ЗАГА'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— (табышмак) әйтелү.

**ЗАГА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. загадить.

**ЗАГА'ЖИВАТЬСЯ** *несов., страд. простореч.*— пычратылу, пычратып бетерелү.

шакшыландырылу, шакшыландырып бетерелү.

**ЗАГАЛДЕ'ТЬ** *сов. разг.*— шаулаша башлау, тавышлана башлау, шаулашырга тотыну.

**ЗАГА'Р** *м. мн.* нет — загар, кояш ашау, тән каралу.

**ЗАГАСА'ТЬ** *несов. устар.*— к. загаснуть.

**ЗАГАСИ'ТЬ** *сов. разг.* — сүндерү, сүндереп бетерү.

**ЗАГА'СНУТЬ** *сов. устар.*— сүнү.

**ЗАГАША'ТЬ** *несов. устар.*— к. загасить.

**ЗАГАША'ТЬСЯ** *несов. страд., устар.*— сүндерелү.

**ЗАГА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. загоститься.

**ЗАГВОЗДИ'ТЬ** *сов. простореч.*— 1. (*вколотить*) кадаклап кую, кагып кую; 2. *перен.* (*начать бить, колотить*) тукмый башлау, дөмбәсли башлау, кыйный башлау; 3. *перен.* колагына туку, кат-кат әйтү; 4. аптыраштa калдыру; *загвоздить вопрос*— сорау белән аптыраштa калдыру.

**ЗАГВО'ЗДКА** *ж. разг.*— 1. *тех.* кадак, чөй (кагып кертелә торган нәрсә); 2. *перен.* комачау, комачаулык, читенлек, кыенлык, хикмәт; *вот в чём загвоздка!* — менә комачаулык кайда! *вся загвоздка в том ...*— бөтен хикмәт шунда ...; 3. *простореч.* киная; *говорить с загвоздками* — кинаялэп сөйләү (суктырып сөйләү).

**ЗАГИ'Б** *м.*— 1. бөгелеш, бөкләнгән урын; *загиб страницы в книге* — китап битенең бөкләнгән урыны; 2. *перен. полит.* тайпылыш; *левый загиб* — сул тайпылыш.

**ЗАГИБА'ТЬ** *несов.*— к. загнуть.

**ЗАГИБА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. загнуться 1; 2. *страд.* кайтарылу.

**ЗАГИ'БЩИК** *м. разг.*— тайпылучы, читкә тайпылучы; *левые загибщики* — сулга тайпылучылар.

**ЗАГИПНОТИЗИ'РОВАТЬ** *сов.*— к. гипнотизировать.

**ЗАГЛА'ВИЕ** *ср.*— исем; *заглавие книги*— китапның исеме.

**ЗАГЛА'ВНЫЙ:** **заглавный лист** — беренче бит (китапның яки бүлекнең исеме язылган беренче бите); **заглавная буква**— баш хәреф (зур хәреф).

**ЗАГЛА'ДИТЬ** *сов.*— 1. тигезләү, үтүкләү; 2. *перен.* йомшарту, төзәтү; *загладить вину* — гаепне төзәтү.

**ЗАГЛА'ДИТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. (*выровняться*) тигезләнү, үтүкләнү; 2. *перен.* басыла башлау; *неприятное впечатление загладилось* — күңелсез тәэсир басыла башлады.

**ЗАГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. загладить.

**ЗАГЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. загладиться; 2. *страд.* тигезләндерелү, үтүкләнү.

**ЗАГЛАЗА'** *нареч. разг.*— 1. үз артында, үзе юк чагында, үзе югында; *заглаза его ругают* — аны үз артында орышалар; 2. *просторeч.* артыгы белән; *этих денег на год ему заглаза хватит* — бу акча аңа бер елга артыгы белән җитәр.

**ЗАГЛА'ЗНО** *нареч. разг.*— үзеннән башка; *его заглазно приняли в школу* — мәктәпкә аны үзеннән башка алдылар.

**ЗАГЛА'ЗНЫЙ** *разг.*— үз артында ...-ган, үзе югында ...-ган, үзеннән башка ...-ган; *заглазные разговоры* — үз артында сөйләнгән сүзләр.

**ЗАГЛА'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. заглотать.

**ЗАГЛА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— йотылу, йотып җибәрелү.

**ЗАГЛОТА'ТЬ** *сов.*— йоту, йотып җибәрү; *щука заглотала живца* — чуртан тере балыкны йотып җибәрде.

**ЗАГЛО'ТОЧНЫЙ** *анат.*— йоткылык артындагы.

**ЗАГЛО'ХЛЫЙ** *обл.*— к. заглохший.

**ЗАГЛО'ХНУТЬ** *сов.*— 1. акрынлану, тыну, ишетелми башлау, тынып калу; *звуки заглохли* — тавышлар тынды; 2. томалану, каплану, ташландык хәлгә килү; *сад заглох* — бакча ташландык хәлгә килгән; 3. сүнү; *самовар заглох* — самовар сүнде; 4. *перен.* тукталып калу; *дело заглохло* — эш тукталып калды.

**ЗАГЛО'ХШИЙ** —1. ташландык, ташландык хәлгә килгән; *заглохший сад*—ташландык хәлгә килгән бакча; 2. *перен.* сүнгән, басылган; *заглохшие воспоминания*—сүнгән истәлекләр.

**ЗАГЛУША'ТЬ** *несов.*— к. заглушить.

**ЗАГЛУША'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. каплану, басылу; 2. *перен.* бастырылу, тукталылу; 3. томалану, каплану; 4. сүндерелү.

**ЗАГЛУШИ'ТЬ** *сов.*— 1. каплау, басу; *оркестр заглушил голос певца* — оркестр җырлаучының тавышын басты (каплады); 2. *перен. книж.* басу, бастыру, туктату; *заглушить боль* — авыртуны (сызлауны) бастыру; 3. басу, томалау, каплау, томалап китү, басып китү; *сорняки заглушили поле* — кырны чүп баскан (каплап киткән); 4. *разг.* сүндерү; *надо заглушить самовар* — самоварны сүндерергә кирәк; 5. *перен. книж.* томалау; *заглушить стремление к свободе* — ирекка омтылышны томалау.

**ЗАГЛУ'ШКА** *ж. тех.*— капкач, томалагыч; (*у самовара*) самовар түбәтәе, калфагы.

**ЗАГЛЯДЕ'НЬЕ** *ср. мн.* нет, *разг.*— карап туйгысыз, күз алгысыз, сокландырырлык, күз чагылдырырлык; *картина — одно загляденье* — карап туйгысыз матур картина.

**ЗАГЛЯДЕ'ТЬСЯ** *сов.*— кузгалмый карап тору, искитеп карап тору, сокланып карап тору, шаккатып карап тору.

**ЗАГЛЯ'ДЫВАТЬ** *несов.*— 1. к. заглянуть; 2. караштыргалау, карап-карап алу; *заглядывать в книгу* — китапка караштыргалау. ◇ **Заглядывать вперёд** *разг.*— киләчәк турында уйлану, иртәгене кайгырту.

**ЗАГЛЯ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.*— заглядеться.

**ЗАГЛЯНУ'ТЬ** *сов.*— 1. (*взглянуть*) күз салу, күз төшерү, карау, карап алу; 2. *разг.* кереп чыгу; *загляну через два дня* — ике көннән кереп чыгармын.

**ЗАГНА'ИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. загноить.

**ЗАГНА'ИВАТЬСЯ** *несов.*— к. загноиться.

**ЗАГНА'ТЬ** *сов.*— 1. куып кертү; *загнать скот во двор* — терлекләрне ишек алдына куып кертү; 2. бәреп кертү; *загнать мяч в ворота противника* — тупны каршы як капкасына бәреп кертү; 3. куып ардыру; куып кертү; куып мендерү; *загнать зверя* — җәнлекне куып ардыру; 4. кагып кертү; *ты слишком глубоко загнал гвоздь*— кадакны бик тирән кагып керткәнсең; 5. *простореч. (продать)* сату, сатып җибәрү, бетү. ◇ **Загнать лошадь** — атны яндыру.

**ЗАГНЕ'ВАТЬСЯ** *сов., простореч. устар.*— ачулана башлау.

**ЗАГНИВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — чери башлау, черү; *загнивание капитализма* — капитализмның черүе.

**ЗАГНИВА'ТЬ** *несов.* — к. загнить.

**ЗАГНИ'ТЬ** *сов.* — черү, чери башлау.

**ЗАГНОИ'ТЬ** *сов.* — 1. эренләтү; үлекләтү; 2. черетү.

**ЗАГНОИ'ТЬСЯ** *сов.* — эренли башлау, эрен белән каплану, үлекли башлау; *рана загноилась* — яра эренли башлаган (эрен белән капланган).

**ЗАГНУ'ТЬ** *сов.* — 1. бөгү; бөкләү, бөкләп кую; *загнуть конец проволоки*—тимер чыбыкның башын бөгү; *загнуть страницу книги* — китап битен бөкләп кую; 2. сызгану; *загнуть брюки* — чалбар балакларын сызгану; 3. *простореч.* борылу, борылып керү; *загнуть за угол* — тыкрыкка борылып керү; 4. *разг. фам.* әйтеп салу, әйтеп ташлау; *он такое словечко загнул* — ул шундый сүз әйтеп ташлады; 5. *разг. (о цене)* үтә кыйммәт сорау, артык бөгеп җибәрү.

**ЗАГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. бөгелү, бөкләнү; 2. *редко (начать гнуться)* бөгелә башлау.

**ЗАГОВА'РИВАТЬ** *несов.* — к. заговорить.

**ЗАГОВА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. заговориться; 2. *разг. (говорить нелепости)* мәгънәсез сүзләр сөйләү (авыру сәбәпле).

**ЗА'ГОВОР** I *м.* — заговор (билгеле бер политик максатка янсә башка берәр максатка ирешү өчен бергәләп эш итү турында бернечә кешенең яки дәүләтнең яшерен сүз куешулары; *заговор империалистов против мира и демократии* — империалистларның тынычлыкка һәм демократиягә каршы заговоры).

**ЗА'ГОВОР** II *м.* — им-том, им-том итү, өшкерү, әфсен-төфсен, әфсенләү; *заговор против зубной боли* — теш авыртуга каршы им-том итү.

**ЗАГОВОРИ'ТЬ** *сов.* — 1. сөйли башлау, тел ачылу; *все разом заговорили* — бөтенесе берьюлы сөйли башладылар; *ребёнок скоро заговорит* — баланың тиздән теле ачылыр; 2. *перен. книж.* уяну, уянып китү, кузгалу; *в нём вдруг заговорила совесть*— кинәт аның вөҗданы уянып китте; 3. *разг. (утомить разговором)* сөйли-сөйли ялыктырып бетерү; сөйләп ардыру; 4. *устар. (заколдовать)*— им-том итү, өшкерү, әфсенләү; 5. *перен.* ата башлау; *пушки заговорили* — туплар ата башлады. ◇ **Заговорить зубы** *перен. разг. фам.* — сүзне читкә борып алдау (алдарга маташу).

**ЗАГОВОРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(увлечься разговором)* сүзгә мавыгып китү; 2. *фам. (завраться)* арттырып җибәрү.

**ЗАГОВО'РЩИК** *м.*, **ЗАГОВО'РЩИЦА** *ж.* — заговорчы, заговорга катнашучы.

**ЗАГОВО'РЩИЦКИЙ**— заговорчылар ...-ы, астыртын; *заговорщицкий план* — заговорчылар планы, астыртын план.

**ЗАГОГОТА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *(о гусях)* кыйкылдый башлау, гаңгылдый башлау, кыйкылдарга (гаңгылдарга) тотыну; 2. *(захохотать)* хахылдап көлә башлау, шаркылдап көлә башлау.

**ЗАГОГУ'ЛИНА** *ж. разг. фам.* — кәкребөкре сызык; *вместо подписи поставили какую-то загогулину* — имза урынына әллә нинди кәкре-бөкре сызык куйганнар.

**ЗА'ГОДЯ** *нареч., простореч. обл.* — к. заблаговременно.

**ЗАГОЛИ'ТЬ** *сов. простореч.* — шәрәләндерү, ачу; *заголить грудь* — күкрәкне ачу.

**ЗАГОЛО'ВОК** *м.* — мәкалә башы, бүлек башы; китап исеме.

**ЗАГОЛО'ВОЧНЫЙ** — бүлекбаш ...-ы; *заголовочный шрифт* — бүлекбаш хәрефе.

**ЗАГОЛОСИ'ТЬ** *сов.* — акыра башлау, бакыра башлау; акырып елый башлау.

**ЗАГОЛУБЕ'ТЬ** *сов.* — зәңгәрләнеп күренә башлау, күгелҗемләнеп күренә башлау; *вдали заголубело море* — еракта зәңгәрләнеп диңгез күренә башлады.

**ЗАГОЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — к. заголить.

**ЗАГОМОНИ'ТЬ** *сов. обл.* — чыр-чу килә башлау, чырылдый башлау.

**ЗАГО'Н** *м.* — 1. *только ед. (действие)* куып кертү; 2. *(для скота)* киртә абзар, утар, ялан абзар, тышкы абзар, кура; *коровы летом ночуют в загоне* — сыерлар җәй көне тышкы абзарда куналар. ◇ **Быть в загоне** *разг.* — кыерсытылу; ташландык хәлдә булу.

**ЗАГО'НЩИК** *м. охот.* — куучы, куып китерүче (ауда җәнлекне).

**ЗАГОНЯ'ТЬ** I *несов.* — к. загнать.

**ЗАГОНЯ'ТЬ** II *сов. разг.* — 1. өшәндерү, талчыктыру, өшәндереп бетерү, хәлдән тайдыру; *лошадь совсем загоняли* — атны бөтенләй өшәндереп бетергәннәр; 2. җәфалап бетерү, аптыратып бетерү; *его загоняли на экзамене* — аны экзаменда аптыратып бетергәннәр.

**ЗАГОНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. куып кертелү; 2. бәреп кертелү; 3. өшәндерелү, талчыктырылу, хәлсезләндерелү.

**ЗАГОРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. загородить 1, 2, 3.

**ЗАГОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. загородиться; 2. *страд.* киртәләнү, койма белән әйләндереп алыну.

**ЗАГОРА'ТЬ** *несов.* — к. загореть.

**ЗАГОРА'ТЬСЯ** *несов.* — к. загореться.

**ЗАГОРДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — тәкәбберләнеп китү, эреләнеп китү, кәпрәеп китү, масаеп китү, кукраеп китү.

**ЗАГОРЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — кайгыра башлау, пошына башлау.

**ЗАГОРЕ'ТЬ** *сов.* — (кояшта) каралу, (кояшта) яну.

**ЗАГОРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. яна башлау, янып китү, кабынып китү; *дом загорелся* — өй яна башлады; 2. *перен.* яна башлау, ялтырый башлау; *глаза у него загорелись* — аның күзләре яна башлады; аның күзләре ялтырый башлады; 3. *перен.* кызып китү; *загорелся спор* — бәхәс кызып китте; 4. ашкыну, кабынып китү; *что вам так загорелось? успеете* — нигә болай ашкынасыз? өлгерерсез. ◇ **Сыр-бор загорелся** — к. бор.

**ЗАГОРЛА'НИТЬ** *сов., просторeч. фам.* — акыра башлау, бакыра башлау.

**ЗАГОРОДИ'ТЬ** *сов.* — 1. әйләндереп алу, киртәләп алу, койма тоту; *загородить двор высоким забором* — ишек алдын биек койма белән әйләндереп алу; 2. каплау; *загородить свет* — яктыны каплау; 3. бикләү; *загородить дорогу* — юлны бикләү; 4. *разг.* тутыру, тутырып бетерү; *загородить весь склад ящиками* — бөтен складны ящиклар белән тутырып бетерү. ◇ **Загородил чепуху (вздор, ерунду)** *простореч. пренебр.* — юк-барны сөйли башлады.

**ЗАГОРОДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(обнестись оградой)* киртәләнү, койма белән әйләндереп алыну; 2. каплану; *загородиться рукой от солнца* — кояштан кул белән каплану.

**ЗАГОРО'ДКА** *ж. разг.* — койма, киртә, читән.

**ЗА'ГОРОДНЫЙ** — шәһәр читендәге, шәһәр тышындагы; *загородный дом* — шәһәр тышындагы йорт.

**ЗАГОРЯЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ярсый башлау, кыза башлау, дулый башлау, ярсып китү; *лошадь загорячилась* — ат ярсый башлады.

**ЗАГОСТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — озак кунак булу, кунакта озак булу.

**ЗАГОТА'ВЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. заготовлять.

**ЗАГОТА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд., разг.* — к. заготовляться.

**ЗАГОТОВИ'ТЕЛЬ** *м.* — хәзерләүче (кеше яки учреждение).

**ЗАГОТОВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — хәзерләү ... -ы; *заготовительная контора* — хәзерләү конторасы.

**ЗАГОТО'ВИТЬ** *сов.* — хәзерләү, хәзерләп кую; *заготовить все документы* — барлык документларны хәзерләп кую; *заготовить дрова* — утын хәзерләп кую.

**ЗАГОТО'ВКА** *ж.* — 1. хәзерләү; *заготовка сельхозпродуктов* — авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү; 2. *сапож.* заготовка (аяк киеме тегү өчен кисеп куелган күн).

**ЗАГОТОВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. заготовить.

**ЗАГОТОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — хәзерләнү, хәзерләп куелу.

**ЗАГОТО'ВОЧНЫЙ** *сапож.* — заготовка ...-ы; *заготовочная мастерская* — заготовка мастерское.

**ЗАГОТО'ВЩИК** *м.* — 1. хәзерләүче; 2. заготовщик, заготовкалар кисүче.

**ЗАГРАБА'СТАТЬ** *сов., простореч. обл.* — эләктерү, тартып алу, талап алу; *он заграбастал чужие деньги* — ул кеше акчасын талап алган.

**ЗАГРА'БИТЬ** *сов. обл.* — талап алу, тартып алу.

**ЗАГРАДИ'ТЕЛЬНЫЙ** — киртәләү ...-ы, тоткарлау ...-ы, комачаулау ...-ы, каплап тору ...-ы; *заградительный огонь* — тоткарлау уты.

**ЗАГРАДИ'ТЬ** *сов.* — бикләү, ябу, киртәләү, каплау; *заградить дорогу* — юлны бикләү, юлны каплау.

**ЗАГРАЖДА'ТЬ** *несов.* — к. заградить.

**ЗАГРАЖДА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — бикләнү, ябылу, каплану.

**ЗАГРАЖДЕ'НИЕ** *ср.* — киртә, заграждение; *минное заграждение* — миналар заграждениесе.

**ЗАГРАНИ'ЦА** *ж. разг.* — чит илләр, заграница.

**ЗАГРАНИ'ЦЕЙ, ЗАГРАНИ'ЦУ** — к. граница.

**ЗАГРАНИ'ЧНЫЙ** — чит ил ...-ы; *заграничные товары* — чит ил товарлары.

**ЗАГРЕБА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. көрәп алу, җыю, җыеп алу; *загребать сено* — печән җыю; 2. *перен.* көрәп алу, сосып алу; *загребать деньги* — акчаны көрәп алу; 3. *простореч.* (ишкәк белән) ишү; *он слишком глубоко загребает* — ул бик тирән ишә. ◇ **Загребать жар чужими руками** — к. жар.

**ЗАГРЕБА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җыеп алыну, җыелу, өелү (тырма, көрәк һ. б. белән).

**ЗАГРЁБИСТЫЙ** *простореч.* — ач күзле, комсыз.

**ЗАГРЕБУ'ЩИЙ** *простореч.* — к. загрёбистый. ◇ **Поповские руки загребущие, глаза завидущие** *послов.* — мулла бир дигәнне яратмый, мә дигәнне генә ярата.

**ЗАГРЕМЕ'ТЬ** *сов.* — 1. күкри башлау, гөрелди башлау, дөберди башлау; *гром загремел* — күк күкри башлады; 2. шыңгырдап китү (кую), шалтырап китү, шалтыр-шолтыр килә башлау; *загремел замок* — йозак шалтырап китте; 3. *перен. простореч. (шумно упасть)* дөбердәп (шалтырап) төшү, шап итеп төшү; 4. янгырау, янгырап китү; *его голос загремел на весь зал* — аның тавышы бөтен залны яңгыратты.

**ЗАГРЕСТИ'** *сов.* — к. загребать.

**ЗАГРИ'ВОК** *м.* — 1. *(у лошади)* ял төбе; 2. *разг. (у человека)* муен тамыры; *ударить по загривку* — муен тамырына утырту.

**ЗАГРИМИРОВА'ТЬ** *сов.* — к. гримировать.

**ЗАГРИМИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* — к. гримироваться.

**ЗАГРОМОЖДА'ТЬ** *несов.* — к. загромоздить.

**ЗАГРОМОЖДА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тутырылу, тутырылып бетү.

**ЗАГРОМОЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — артык тутырылу; киракcез (артык) нәрсәләр белән тутырылу.

**ЗАГРОМОЗДИ'ТЬ** *сов.* — тутыру, тутырып бетерү.

**ЗАГРОМЫХА'ТЬ** *сов. разг.* — дөберди башлау, дыңгырдый башлау, шыңгырдый башлау, шалтыр-шолтыр килә башлау; дөбер-шатыр килә башлау.

**ЗАГРОХОТА'ТЬ** *сов. разг.* — күкри башлау, гөрселди башлау, дөберди башлау; *пушки загрохотали* — туплар гөрселди башлады; *гром загрохотал* — күк күкри башлады.

**ЗАГРУБЕ'ЛЫЙ** — тупасланган, кытыршыланган, каткан; *загрубелые руки* — тупасланган куллар.

**ЗАГРУБЕ'ТЬ** *сов.* — 1. *(стать жёстким)* тупаслану, катылану, кытыршылану; 2. *разг. фам. (стать грубым)* тупаслану, дорфалану, кыргыйлану.

**ЗАГРУЖА'ТЬ** *несов.* — к. загрузить.

**ЗАГРУЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. загрузиться; 2. *страд.* тутырылу, тутырылып бетү.

**ЗАГРУ'ЖЕННОСТЬ, ЗАГРУЖЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. йөкнең күп булуы; *загружённость железных дорог* — тимер юлларда йөкнең күп булуы; 2. *перен.* күп булу; *загружённость работой* — эшнең күп булуы.

**ЗАГРУЗИ'ТЬ** *сов.* — 1. тутыру, тутырып бетерү; *загрузить все подвалы картошкой* — барлык подвалларны бәрәңге белән тутырып бетерү; 2. *перен.* житәрлек эш йөкләү, эш белән тәэмин итү; *загрузить секретаря* — секретарьга житәрлек эш йөкләү.

**ЗАГРУЗИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. төялү, тулганчы төялү; 2. житәрлек эш алу.

**ЗАГРУ'ЗКА** *ж.* — 1. *только ед. (действие)* тутыру, төяү; 2. загрузка; *завод имеет полную загрузку* — завод тулы загрузка белән эшли.

**ЗАГРУ'ЗОЧНЫЙ** *тех.* — төйи торган, төяү ...-ы; *загрузочная машина* — төйи торган машина, йөк төяү машинасы.

**ЗАГРУ'ЗЧИК** *м. спец.* — төяүче (эшче).

**ЗАГРУНТОВА'ТЬ** *сов.* — к. грунтовать.

**ЗАГРУНТО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. загрунтовать.

**ЗАГРУНТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — к. грунтоваться.

**ЗАГРУСТИ'ТЬ** *сов.* — ямансылый башлау, сагына башлау, юксына башлау.

**ЗАГРЫЗА'ТЬ** *несов.* — к. загрызть.

**ЗАГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. талап үтерелү; 2. *перен.* интектерелү.

**ЗАГРЫ'ЗТЬ** *сов.* — 1. талап үтерү; *собаки загрызли кошку* — этләр мәчене талап үтергәннәр; 2. *перен. разг. (замучить)* жәфалау, жәфалап бетерү, интектерү, интектереп бетерү.

**ЗАГРЯЗНИ'ТЬ** *сов.* — пычрату, каралту, керләндерү.

**ЗАГРЯЗНИ'ТЬСЯ** *сов.* — пычрану, каралу, керләнү.

**ЗАГРЯЗНЯ'ТЬ** *несов.* — к. загрязнить.

**ЗАГРЯЗНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. загрязниться; 2. *страд.* пычратылу, каралтылу; керләндерелү.

**ЗАГУБИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *(привести к гибели)* харап итү, һәлак итү; башына житү, башын ашау; 2. әрәм итү; туздыру; *я много средств зря загубил* — күп акчаны юкка гына әрәм иттем.

**ЗАГУДЕ'ТЬ** *сов.* — 1. кычкырта башлау; *на заводе загудел гудок* — заводта гудок кычкырта башлады; 2. шаулый башлау; *загудел лес* — урман шаулый башлады; *загудел самовар* — самовар шаулый башлады; 3. шалтырый башлау, даң-доң итә башлау; *загудели колокола* — кыңгыраулар даң-доң итә башлады; 4. улый башлау; *загудел ветер* — жил улый башлады; 5. гөж килә башлау, гөжли башлау; *загудели пчёлы* — умарта кортлары гөжли башлады.

**ЗАГУ'ЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. загулять.

**ЗАГУ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. загуляться.

**ЗАГУЛЯ'ТЬ** *сов. разг.* — эчкелеккә бирелеп китү, эчәргә бирелү, типтерә башлау.

**ЗАГУЛЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. йөрү белән мавыгу, озак йөрү; 2. дөньясын онытып күңел ачу, типтерү.

**ЗАГУСТЕ'ТЬ** *сов.* — куеру.

**ЗАГУСТИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — куерткыч (буяуны куерта торган матдәләр — крахмал, казеин, альбумин һ. б.).

**ЗАГУСТИ'ТЬ** *сов.* — куерту.

**ЗАГУСТИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. загустеть.

**ЗАГУТО'РИТЬ** *сов. обл.* — шаулап сөйләшә башлау.

**ЗАД** *м.* — 1. арт, арт як; *зад телеги* — арба арты; *надеть платье задом наперёд* — күлмәкнең артын алга кию; 2. *(задняя часть тела)* арт сан; 3. *только мн. обл.* абзар арты, бакча арты; 4. *только мн. разг.* үткәннәр; *повторять зады* — үткәннәрне кабатлау.

**ЗАДА'БРИВАТЬ** *несов. разг.* — к. задобрить.

**ЗАДАВА'ЛЬЩИК** *м.* — машинага ... биреп торучы; *задавальщик при молотилке* — (ашлык) сугу машинасына көлтә биреп торучы.

**ЗАДАВА'ТЬ** *несов.* — к. задать.

**ЗАДАВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. задаться; 2. *страд.* бирелү; *уроки задаются на дом* — дәресләр өйгә бирелә; салыну, бирелү (мәсәлән, атка солы); биреп торылу, салып торылу (мәсәлән, сугу машинасына көлтә); оештырылу, бирелү, ясалу (мәсәлән, берәр кунак хөрмәтенә аш мәжлесе оештырылу); 3. *простореч.* масаю, кәпрәю, борын күтәрү, эреләнү.

**ЗАДАВИ'ТЬ** *сов.* — **1.** басып үтерү, сытып үтерү, таптап үтерү; *задавил трамвай* — трамвай таптап үтергән; **2.** буып үтерү; *кошка задавила цыплёнка* — мәче чебешне буып үтергән; **3.** *перен. (подавить, заглушить)* басу, буу, изү.

**ЗАДА'НИЕ** *ср.* — задание, бирем, йөкләмә.

**ЗАДА'РИВАТЬ** *несов.* — к. задарить.

**ЗАДА'РИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — мул итеп бүләкләнү, бүләк белән күмелү, күп бүләк бирелү.

**ЗАДАРИ'ТЬ** *сов.* — **1.** *(осыпать подарками)* мул итеп бүләкләү, күп бүләк бирү, бүләк белән күмү; **2.** *(подкупить, задобрить)* бүләк биреп сатып алу, бүләк биреп үзенә карату.

**ЗАДАРМА', ЗАДА'РОМ** *нареч. просторечь.* — к. даром.

**ЗАДА'ТКИ** *ед.* нет — өмет, сәләтлелек билгеләре; *у этого ребёнка хорошие задатки* — бу бик өметле бала.

**ЗАДА'ТОК** *м.* — задатка (әйбер өчен түләнәчәк акчаның алдан бирелә торган өлеше).

**ЗАДА'ТОЧНЫЙ** — задатка ...-ы; *задаточная сумма* — задатка суммасы.

**ЗАДА'ТЬ** *сов.* — **1.** бирү; *задать работу* — эш бирү; *задать вопрос* — сорау бирү; **2.** салу, бирү; *задать лошади овса* — атка солы салу; **3.** *разг. фам.* оештыру, ясау; *задать вечер* — кичә оештыру. ◇ **Задать перцу** — кирәген бирү. **Задать страху** — котын алу (чыгару). **Задать баню** — мунча кертү (кыздыру, бик нык шелтәләү, тиргәү).

**ЗАДА'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** ... итеп кую; *задаться целью изучить языки* — телләр өйрәнүне максат итеп кую; **2.** *просторечь.* булып чыгу, барып чыгу; *дело ему не задалось* — аның эше барып чыкмады.

**ЗАДА'ЧА** *ж.* — **1.** *(цель, поручение)* бурыч, йомыш, вазифа; **2.** мәсьәлә; *арифметическая задача* — арифметик мәсьәлә; *это неразрешимая задача* — бу чишелмәслек мәсьәлә; **3.** *обл. (удача, счастье)* уңыш, бәхет.

**ЗАДА'ЧЛИВЫЙ** *просторечь.* — бәхетле, уңышлы; *задачливый человек* — бәхетле кеше; *задачливое дело* — уңышлы эш.

**ЗАДА'ЧНИК** *м.* — мәсьәләләр җыентыгы (математика буенча).

**ЗАДВИ'ГАТЬ** *сов.* — кузгата башлау, кыймылдата башлау; хәрәкәткә китерү; кузгатып җибәрү.

**ЗАДВИГА'ТЬ** *несов.* — к. задвинуть.

**ЗАДВИ'ГАТЬСЯ** *сов.* — кузгала башлау, хәрәкәт итә башлау, хәрәкәткә килү.

**ЗАДВИГА'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. задвинуться; **2.** *страд.* шудырып йөртелү, этеп йөртелү.

**ЗАДВИ'ЖКА** *ж.* — эшермә; эшермә бик.

**ЗАДВИЖНО'Й** — эшермәле, шудырмалы; *задвижная дверь* — шудырмалы ишек.

**ЗАДВИ'НУТЬ** *сов.* — **1.** этеп кертү; этеп кую; *задвинуть ящик стола* — өстәл тартмасын этеп кертү; **2.** *разг. (запереть)* бикләү, бикләп кую; **3.** *разг. (закрыть чем-н. подвижным)* каплау, каплап кую.

**ЗАДВИ'НУТЬСЯ** *сов.* — **1.** эчкә кереп китү; *ящик в столе задвинулся* — өстәл тартмасы эчкә кереп киткән; **2.** ябылу, бикләнү; *дверца задвинулась* — ишек ябылды (бикләнде).

**ЗАДВОИ'ТЬСЯ** *сов.* — ике булып күренә башлау.

**ЗАДВО'РКИ** *мн.* — **1.** абзар арты, өй арты; **2.** *перен. разг. фам.* караңгы почмак, арт урам; *он живёт на задворках* — ул арт урамда тора; **3.** *перен. разг. фам.* соңгы бит, кеше күрми торган урын; *его заметку поместили на задворках* — аның мәкаләсен кеше күрми торган урынга урнаштырганнар.

**ЗАДЕВА'ТЬ** I *несов.* — к. задеть.

**ЗАДЕВА'ТЬ** II *сов. разг.* — кую; *я кудато книгу задевал* — китапны әллә кая куйганмын.

**ЗАДЕВА'ТЬСЯ** *сов.* — булу, китү, югалу; *куда же задевалась эта книга?* — бу китап кая киткән соң? *куда вы задевались?* — сез кая югалдыгыз?

**ЗАДЕКЛАМИ'РОВАТЬ** *сов.* — декламация сөйли башлау.

**ЗАДЕ'ЛАТЬ** *сов.* — **1.** томалау, томалап кую; *заделать слуховое окно* — ян тәрәзәне томалап кую; **2.** кадаклап кую; *заделать ящик* — ящикны кадаклап кую.

**ЗАДЕ'ЛАТЬСЯ** *сов. просторечь.* — булып китү; *заделаться специалистом* — специалист булып китү.

**ЗАДЕ'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. заделать.

**ЗАДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. просторечь.* — к. заделаться.

**ЗАДЁРГАТЬ** *сов.* — **1.** тарткалый башлау; *задёргать вожжами* — дилбегәне тарткалый башлау; **2.** *перен. разг. (измучить)* интектереп бетерү, тенкәгә тиеп бетү. ◇ **Лошадь задёргала ушами** — ат колакларын селкетә башлады.

**ЗАДЁРГАТЬСЯ** *сов.* — тартыша башлау, калтырана башлау; *руки у него задёргались* — аның куллары тартыша башлады.

**ЗАДЁРГИВАТЬ** I *несов. разг.* — к. задёргать 2.

**ЗАДЁРГИВАТЬ** II *несов.* — к. задёрнуть.

**ЗАДЕРЕВЕНЕ'ТЬ** *сов.* — **1.** *(затвердеть)* агач кебек кату; **2.** *перен.* ою, кату (тоймаслану); *у меня руки и ноги задеревенели от стужи* — туңудан аяк-кулларым катты.

**ЗАДЕРЖА'ТЬ** *сов.* — **1.** тоту, тотып калу; *дела меня задержали* — мине эшләр тотты; **2.** кичектерү, соңга калдыру; *выдачу зарплаты задержали на два дня* — хезмәт хакын түләүне ике көнгә кичектерделәр; **3.** тоткарлау, комачаулау; *болезнь сильно задержала развитие ребёнка* — авыру баланың үсешен бик нык тоткарлады; **4.** туктату; *задержать дыхание* — сулыш алуны туктату; **5.** кулга алу, арестовать итү, тоту; *задержать на месте преступления* — җинаять урынында тоту.

**ЗАДЕРЖА'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** тотылып тору; тоткарлану, кичегү, яту; *он задержался в*

*дороге* — ул юлда кичеккән; *письмо задержалось на почте* — хат почтада яткан; 2. тоткарлану, тоткарланып тору; *развитие ребёнка несколько задержалось* — баланың үсүе бераз тоткарланып торды; 3. тукталу, туктап калу, акрынаю; *дыхание задержалось* — сулышы акрынайды.

**ЗАДЕ'РЖИВАТЬ** *несов.*— к. задержать.

**ЗАДЕ'РЖИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. задержаться; 2. *страд.* кулга алыну, арестовать ителү, тотылу.

**ЗАДЕ'РЖКА** *ж.* — 1. *(приостановка)* тукталып тору, тукталып калу; 2. *(промедление)* тоткарлык; 3. *(опоздание)* сонга калу, кичегү.

**ЗАДЕРНОВА'ТЬ** *сов.* — кәс җәю, кәс белән каплау.

**ЗАДЁРНУТЬ** *сов.*— (пәрдәне) тарту, (пәрдә) төшерү, (пәрдә белән) каплау.

**ЗАДЕ'ТЬ** *сов.*— 1. эләктерү, бәрелү, бәрелеп китү, орыну, тиеп китү; *птица задела его крылом* — кош аңа канаты белән бәрелеп китте; 2. кәефкә тию; хәтер калдыру; *его слова меня задели* — аның сүзләре минем хәтерне калдырды.

**ЗА'ДЕШЕВО, ЗАДЁШЕВО** *нареч. просторен.*— арзанга, арзан хакка.

**ЗАДИ'РА** *м.* и *ж. разг. фам.* — бәйләнчек, сугыш чукмары.

**ЗАДИРА'ТЬ** *несов. разг.* — к. задрать 1, 2, 4.

**ЗАДИРА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— к. задраться I.

**ЗАДНЕНЁБНЫЙ** *лингв.* — арткы аңкау ...-ы; *задненёбные звуки* — арткы аңкау авазлары.

**ЗАДНЕЯЗЫ'ЧНЫЙ** *лингв.* — тел арты ...-ы; *заднеязычные звуки* — тел арты авазлары.

**ЗА'ДНИЙ** — арткы, арт ...; арттагы; *заднее колесо* — арткы тәгәрмәч; *задние ноги* — арт аяклар. ◇ **Задняя мысль** — яшерен фикер. **Быть без задних ног** *разг.*— бик нык ару, арып егылу, аяксыз калу. **Задним числом** — үткән число белән. **Ходить на задних лапах** *разг.*— ялагайлану.

**ЗА'ДНИК** *м.* — задник, үкчә арты (аяк киемендә).

**ЗАДО'БРИТЬ** *сов. разг.* — үзенә карату, юмалап үзенә карату.

**ЗАДО'К** *м.*— 1. арт, арткы як; *задок телеги* — арба арты; *задок дивана* — диван арты; 2. *сапож.* задник.

**ЗАДОЛБИ'ТЬ** *сов.*— 1. *(начать долбить)* чокый башлау, чокып казый башлау; 2. *разг. (заучить тупо)* башка туку; аңламыйча ятлау, мәгънәсенә төшенмичә ятлау.

**ЗАДО'ЛГО** *нареч. разг.*— күп элек, күп алдан; *мы приехали на пристань задолго до отхода парохода* — пристаньга без пароход китүдән күп элек килдек.

**ЗАДОЛЖА'ТЬ** *сов. разг.*— бурычка керү, бурычлану.

**ЗАДОЛЖА'ТЬСЯ** *сов., разг. обл.* —бурычка бату.

**ЗАДО'ЛЖЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — бурыч, бирәчәк, бирәсе; *задолженность по квартирной плате* — квартира өчен бирәчәк; *погасить задолженность* — бурычны түләп бетерү.

**ЗА'ДОМ** *м. нареч. разг.* — арт белән, артка таба.

**ЗАДО'Р** *м. мн.* нет — 1. дәрт, ялкын; 2. кызулык; ярсып китүчәнлек; 3. к. задорина.

**ЗАДО'РИНА** *ж.* — кытыршылык, чокыр, уенты, ботак урыны.

**ЗАДО'РИНКА** *ж.* — к. задорина. ◇ **Ни сучка, ни задоринки (или без сучка, без задоринки)** — шома гына, шоп-шома гына, бик шома; ул-бусыз гына.

**ЗАДО'РИТЬСЯ** *несов. просторен.*— ярсу, кызу.

**ЗАДО'РНЫЙ** — 1. *(пылкий)* дәртле, ялкынлы; 2. кызу, кызып китүчән; *задорный парень* — кызып китүчән егет.

**ЗА'ДО'РОГО** *нареч. просторен.* — кыйбатка, кыйбат бәягә; *продать задорого* — кыйбат бәягә сату.

**ЗАДО'ХЛИК** *м. спец.*— үле чеби, йомырка эчендә үлгән чеби.

**ЗАДОХНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (томчыгып) үлү, (тын бетеп) үлү; *задохнуться от угара* — ис тиеп үлү; 2. тын бетү, сулыш тарау, тын кысылу; *задохнуться от бега* — йөгерүдән тын бетү.

**ЗАДРА'ЗНИВАТЬ** *несов. разг.* — к. задразнить.

**ЗАДРАЗНИ'ТЬ** *сов. разг.* — үртәп йөдәтеп бетерү, үртәп теңкәсенә тию, үчекләп йөдәтеп бетерү, үчекләп теңкәсенә тию.

**ЗАДРАПИРОВА'ТЬ** *сов.*— 1. *(одеть, окутать)* бөркәндерү, төрү; 2. драпировать итү, пәрдәләү, бизәү; *окно задрапировать бархатом* — тәрәзәне бархат белән пәрдәләү.

**ЗАДРАПИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* — бөркәнү, каплану, төренү; *задрапироваться в плащ* — плащ бөркәнү, плащка төренү.

**ЗАДРАПИРО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к задрапировать.

**ЗАДРАПИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. задрапироваться; 2. *страд.* пәрдәләнү.

**ЗАДРА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. күтәрү, кайтару; *задрать голову* — башны күтәрү; *задрать платье* — күлмәкне кайтару; 2. тырнау, сыдыру; *задрать кожицу на пальце* — бармак тиресен сыдыру; 3. *обл.* талап үтерү, буу, буып үтерү; *волк задрал овцу* — бүре сарыкны буып үтергән; 4. бәйләнү; *первые задрали соседские мальчики* — беренче булып күрше малайлары бәйләнделәр. ◇ **Задрать нос** — борын күтәрү, үзен әллә кемгә санау, масая башлау.

**ЗАДРА'ТЬСЯ** I *сов. разг.*— 1. кайтарылу, күтәрелү; *платье задралось кверху* — күлмәк итәге югарыга кайтарылган; 2. суелу, сыдырылу; *кожица задралась на пальце* — бармак тиресе суелган.

**ЗАДРА'ТЬСЯ** II *сов. просторен.* — сугыша башлау; *мальчишки задрались* — малайлар сугыша башладылар.

**ЗАДРЕБЕЗЖА'ТЬ** *сов.* — дерелди башлау, чылтырый (челтери) башлау; дерелдэп (чылтырап) китү.

**ЗАДРЕМА'ТЬ** *сов.* — йокымсырау, йокымсырый башлау, йокымсырап китү, йокыга китә башлау.

**ЗАДРОЖА'ТЬ** *сов.* — калтырый башлау, дерелди башлау, калтырана башлау.

**ЗАДРЫ'ГАТЬ** *сов., разг. фам.* — тыпырчына башлау.

**ЗАДУБА'СИТЬ** *сов., разг. фам.* — 1. дөбердәтә башлау, кага башлау; *задубасить кулаками в дверь* — йодрык белән ишекне дөбердәтә башлау; 2. дөмбәсли башлау.

**ЗАДУВА'ТЬ** *несов.* — 1. к. задуть 2, 3; 2. *простореч.* элдертә бирү, әйттерә бирү; *задувает на гармошке* — гармоньда әйттерә бирә.

**ЗАДУВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. өреп сүндерелү; 2. кабызып җибәрелү.

**ЗАДУ'МАТЬ** *сов.* — 1. уйлау, исәп итү, ниятләү; *задумать поехать в Москву* — Москвага барырга исәп итү (уйлау); 2. уйлау, уйлап кую, күңелдән уйлау; *задумать какое-н. число* — нинди дә булса бер сан уйлау (уйлап кую).

**ЗАДУ'МАТЬСЯ** *сов.* — 1. уйлау, уйлану; *приходится задуматься, как выйти из этого положения* — бу хәлдән ничек чыгу турында уйларга (уйланырга) туры килә; 2. уйга калу, уйга бату, уйга чуму; *он задумался, глядя в окно* — тәрәзәдән карап ул уйга калды; 3. уйлап тору; *он и не задумался прыгнуть с такой высоты* — андый биеклектән сикерү турында ул уйлап та тормады.

**ЗАДУ'МЧИВО** *нареч.* — уйланып, уйга батып.

**ЗАДУ'МЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — уй; *впасть в задумчивость* — уйга төшү; *погрузиться в задумчивость* — уйга бату, уйга чуму.

**ЗАДУ'МЧИВЫЙ** — уйчан, уйланучан; *задумчивый взгляд* — уйчан караш.

**ЗАДУ'МЫВАТЬ** *несов.* — к. задумать.

**ЗАДУ'МЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. задуматься; 2. *страд.* уйланылу; 3. *простореч.* *(впадать в меланхолию)* күңел төшенкелегенә бирелү.

**ЗАДУРИ'ТЬ** *сов., разг. фам.* — шаяра башлау; чорсызлана башлау, юньсезләнә башлау; *(о лошади)* чыгымчылый башлау. ◇ **Задурить голову** *простореч.* — башынкүзен әйләндерү.

**ЗАДУ'ТЬ** *сов.* — 1. *(начать дуть)* исә башлау, өрә башлау; 2. сүндерү, өреп сүндерү; *задуть огонь* — утны өреп сүндерү; 3. *тех.* кабызып җибәрү, яндырып җибәрү; *задуть домну* — домнаны кабызып җибәрү.

**ЗАДУШЕ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — эчкерсезлек, чын күңелдән булу; *задушевность наших бесед* — безнең әңгәмәләрнең чын күңелдән булуы.

**ЗАДУШЕ'ВНЫЙ** — эчкерсез, чын, чын күңелдән...; *задушевный друг* — чын дус (эчкерсез дус); *задушевный разговор* — чын күңелдән сөйләшү.

**ЗАДУШИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(умертвить)* буу, буып үтерү, томалап үтерү, тончыктырып үтерү; 2. *(лишить возможности дышать)* тынны бетерү, тынны кысу; 3. *(подавить)* басу, томалау. ◇ **Задушить в объятиях** — кысып-кысып кочаклау.

**ЗАДУШИ'ТЬСЯ** *сов., простореч. обл.* — буылу, тын кысылу, тын бетү.

**ЗАДЫМИ'ТЬ** *сов.* — 1. төтенли башлау, төтен чыгара башлау, (төтен) кайтара башлау; *печка задымила* — мич (төтен) кайтара башлады; 2. *разг. фам.* төтенләү, төтен белән тутыру, төтен белән каралтып бетерү; *весь потолок задымили* — бөтен түшәмне төтен белән каралтып бетергәннәр.

**ЗАДЫМИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. төтен чыга башлау; *трубы задымились* — трубалардан төтен чыга башлады; 2. *(покрыться копотью)* корымлану, корым белән каплану. ◇ **Река задымилась** — елга өстеннән томан күтәрелә башлады.

**ЗАДЫХА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. задохнуться; 2. *перен.* кысылу, тын да ала алмау, интегү; *крестьянство задыхалось под игом рабства* — крестьяннар коллык изүе астында интегәләр иде.

**ЗАДЫША'ТЬ** *сов.* — сулый башлау, тын ала башлау, сулыш ала башлау.

**ЗАЕГОЗИ'ТЬ** *сов. разг.* — боргалана башлау, кыбырсыклана башлау.

**ЗАЕДА'ТЬ** *несов.* — к. заесть.

**ЗАЕДА'ТЬСЯ** *несов.* — *к.* заесться.

**ЗАЁЖИТЬСЯ** *сов.* — 1. бөрешә башлау, куырыла башлау; 2. *перен.* ояла башлау.

**ЗАЕ'ЗД** *м.* — 1. *спорт.* заезд; 2. керү, кереп чыгу.

**ЗАЕ'ЗДИТЬ** *сов.* — 1. *(замучить ездой)* йөртеп алҗыту, йөртеп өшәндерү; йөртеп хәлдән тайдыру; 2. *перен. разг. фам. (замучить)* алҗытып бетерү, интектереп бетерү, теңкәгә тию; 3. *простореч. (истоптать)* таптатып бетерү; 4. *простореч. (начать ездить)* йөри башлау.

**ЗАЕ'ЗДОМ** *нареч. простореч.* — үтеп барышлый, юл уңаенда.

**ЗАЕЗЖА'ТЬ** *несов.* — к. заехать.

**ЗАЕ'ЗЖИЙ** *разг.* — узгынчы, юлаучы, килгән (кеше).

**ЗАЁКАТЬ** *сов. разг.* — (йөрәк) кага башлау, (йөрәк) тибә башлау; леп-леп итә башлау; *сердце у меня заёкало* — минем йөрәгем леп-леп итә башлады.

**ЗАЕЛО'ЗИТЬ** *сов., простореч.* — 1. шуыша башлау, үрмәли башлау, мүкәли башлау; 2. шуышып пычратып бетерү.

**ЗАЁМ** *м.* — 1. заём; *государственный заём* — дәүләт заёмы; 2. *разг.* бурыч, күтәргә алынган акча; *он постоянно жил займами* — ул һәрвакыт бурычка алган акчага тора иде.

**ЗАЁМЩИК**, *м.*, **ЗАЁМЩИЦА** *ж. юр.* — бурычка алучы.

**ЗАЁРЗАТЬ** *сов.* — 1. кыбырсыклана башлау, тик утырмый башлау, боргалана баш-

лау; 2. *простореч.* кыбырсыкланып таушалдырып бетерү.

**ЗАЕ'СТЬ** *сов. разг.*— 1. талап үтерү, буып үтерү; *волк заел овцу* — бүре сарыкны буып үтергән; 2. *перен. разг.* (*извести*) җәфалау, теңкәгә тию, үзәккә үтү; 3. артыннан кабу, кабып җибәрү; *лекарство заесть конфетой* — дару артыннан конфет кабып җибәрү; 4. кысу, кыстыру, эләктерү; *блок заел верёвку* — блок бауны кыстырды; 5. *обл.* үзләштерү, ашау; *заел мои денежки* — минем акчамны ашады (үзләштерде).

**ЗАЕ'СТЬСЯ** *сов. простореч.*— талымлау.

**ЗАЕ'ХАТЬ** *сов.*— 1. керү; *заехать во двор* — ишек алдына керү; 2. кереп чыгу; *заехать к знакомым* — таныш-белешләргә кереп чыгу; 3. алырга керү; *заехать за детьми* — балаларны алырга керү; 4. әйләнеп керү, урап керү; *заехать со стороны сада* — бакча ягыннан әйләнеп керү; 5. артына барып чыгу, аръягына барып чыгу; *заехать за мост* — күпер аръягына барып чыгу; 6. *разг.* барып керү, барып төшү; *заехать в канаву* — канауга барып керү; 7. *простореч. вульг.* кундыру, менеп төшү; *заехать в физиономию* — яңагына кундыру.

**ЗАЖА'РИВАТЬ** *несов.* — 1. к. зажарить 1; 2. сиптерү, элдертү; *ишь, как зажаривает (бежит)* — кара син аны, ничек элдертә.

**ЗАЖА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. зажариться; 2. *страд.* кыздырылу, куырылу.

**ЗАЖА'РИТЬ** *сов.* — 1. кыздыру, кыздырып пешерү; куыру, куырып пешерү; 2. *простореч.* әйттерә башлау, сиптерә башлау; *парень зажарил на гармошке* — егет гармоньда әйттерә башлады.

**ЗАЖА'РИТЬСЯ** *сов.* — куырылып җитү, кыздырылып җитү.

**ЗАЖА'ТЬ** *сов.*— 1. (*стиснуть*) кысып тоту, кысу; 2. каплау; *зажать уши* — колакны каплау; 3. *перен. разг.* басу, кысу, юл куймау, томалау; *зажать инициативу* — инициативаны кысу. ◇ **Зажать рот** *перен.* авызын каплау.

**ЗАЖА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кысылу, кысылып калу.

**ЗАЖДА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — көтә-көтә арып бетү, көтә-көтә көтек булу.

**ЗАЖЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — чәйни башлау, чәйнәргә тотыну.

**ЗАЖЕЛТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. саргая башлау; *рожь зажелтела* — арыш саргая башлаган; 2. сары ... күренә башлау (сары әйбер турында); *вдали зажелтели кучи песку* — еракта сары ком өемнәре күренә башлады.

**ЗАЖЕЛТЕ'ТЬСЯ** *сов.*— к. зажелтеть 2.

**ЗАЖЕЛТИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (*закрасить желтой краской*) сарыга буяу, сарыга манну; 2. сарыга буяп бетерү (пычрату); *она зажелтила всё платье* — ул бөтен күлмәген сарыга буяп бетергән.

**ЗАЖЕМА'НИТЬСЯ** *сов. разг.* — назлана башлау, кылана башлау, кыстата башлау.

**ЗАЖЕСТИКУЛИ'РОВАТЬ** *сов.*— (сөйләгәндә) кулларны селти башлау.

**ЗАЖЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. кабызу, яндыру, кабызып җибәрү, яндырып җибәрү; *зажечь спичку* — шырпы кабызу; 2. *перен. книж.* уяту, дәртләндерү, ялкынландыру, дәртләндереп җибәрү; *речь агитатора зажгла слушателей* — агитаторның сүзләре тыңлаучыларны дәртләндерде.

**ЗАЖЕ'ЧЬСЯ** *сов.*— 1. кабыну, янып китү, кабынып китү; *зажглись огни* — утлар кабынып китте; 2. *перен. книж.* уянып китү, дәртләнү, кабыну, кабынып китү; *зажечься ненавистью к врагу* — дошманга нәфрәт тойгысы кабынып китү.

**ЗАЖИВА'ТЬ** *несов.*— к. зажить 1.

**ЗАЖИВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. зажиться.

**ЗАЖИВИ'ТЬ** *сов.*— (дәвалап) төзәтү.

**ЗАЖИВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. заживить.

**ЗАЖИВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— (дәвалап) төзәтелү.

**ЗА'ЖИВО** *нареч. разг.* — терелэй, тере килеш, терелэтә.

**ЗАЖИГА'ЛКА** *ж.*— зажигалка, уткабызгыч.

**ЗАЖИГА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. яндыра торган; *зажигательная бомба* — яндыра торган бомба; 2. *перен.* ялкынлы, ялкынландыра торган, дәртләндерә торган; *зажигательная речь* — ялкынлы речь.

**ЗАЖИГА'ТЬ** *несов.*— к. зажечь.

**ЗАЖИГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. зажечься; 2. *страд.* кабызылу, яндырылу; 3. *страд. перен.* дәртләндерелү, ялкынландырылу.

**ЗАЖИ'ЛИТЬ** *сов. простореч.* — йомып калу, кысып калу (бурычка алганны кайтарып бирмәү).

**ЗАЖИ'М** *м.* — 1. *только ед.* (*действие*) кысу, басу, буу; *бороться с попытками зажима критики и самокритики* — тәнкыйть һәм үзара тәнкыйтьне кысарга теләүчеләргә каршы көрәшү; 2. *тех.* (*прибор*) кыскыч, кыстыргыч, зажим.

**ЗАЖИМА'ТЬ** *несов.*— к. зажать.

**ЗАЖИМА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. зажаться; 2. *страд.* кыстырылу; каплану; 3. *перен.* томалану, кысылу, юл куелмау.

**ЗАЖИ'МИСТЫЙ** *простореч.* — 1. каты кыса торган, каты кысучан, көчле; 2. *перен.* саран; *зажимистый человек* — саран кеше.

**ЗАЖИ'МЩИК** *м.*, **ЗАЖИ'МЩИЦА** *ж. разг. неодобр.*— кысучы; *зажимщик критики* — тәнкыйтьне кысучы.

**ЗАЖИРЕ'ЛЫЙ** *обл.* — артык симергән, май баскан.

**ЗАЖИРЕ'ТЬ** *сов. обл.* — артык симерү, май басу.

**ЗАЖИТО'Е** *сущ.*— эшләп табылган акча.

**ЗАЖИ'ТОЧНО** *нареч.*—мул, иркен; *жить зажиточно* — мул яшәү, иркен яшәү.

**ЗАЖИ'ТОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — таза тормышлылык, нык тормышлылык, мул тормышлылык, иркен тормышлылык, таза тормышлы булу, мул тормышлы булу.

**ЗАЖИ'ТОЧНЫЙ** — таза тормышлы, нык тормышлы, мул тормышлы, иркен тормыш-

лы; *зажиточный колхозник* — таза тормышлы колхозчы.

**ЗАЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(о ране)* төзәлү, төзәлеп житү; 2. тора башлау, яши башлау, тормыш корып җибәрү; *зажить по-новому* — яңача тора башлау, яңача яши башлау, яңача тормыш корып җибәрү.

**ЗАЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. озак тору, артык озак тору; *мы зажились в деревне, пора ехать домой* — без авылда артык күп тордык, өйгә кайтырга вакыт; 2. артык озак яшәү, күп гомер итү; *старик зажился* — карт озак яшәде.

**ЗАЖМУ'РИТЬ** *сов.* — к. жмурить.

**ЗАЖМУ'РИТЬСЯ** *сов.* — к. жмуриться.

**ЗАЖО'Р** *м. обл.* — 1. *(затор льда)* тыгылган бозлар (яз көве боз киткәндә елгада); 2. *(вода под снегом)* кар астына җыелган су.

**ЗАЖУРЧА'ТЬ** *сов.* — челтерәп ага башлау.

**ЗАЖУ'ХЛЫЙ** *обл.* — 1. *(ставший тусклым)* тоныклавган (буяу); 2. *(ставший тухлым)* сөрсегән, сасыган.

**ЗАЖУ'ХНУТЬ** *сов. обл. спец.* — 1. тоныклану (буяу яки лак белән буялган әйбер турында); 2. кибеп кату (күн турында).

**ЗАЗВА'ТЬ** *сов. разг.* — кыстап, чакырып китерү, чакырып кертү.

**ЗАЗВЕНЕ'ТЬ** *сов.* — шалтырый башлау, чылтырый башлау; яңгырый башлау; *зазвенел колокольчик* — кыңгырау шалтырый башлады; *зазвенел детский смех* — балалар көлүе янгырый башлады.◇ Зазвенело в ушах — колакларым шаулап китте.

**ЗАЗВОНИ'ТЬ** *сов.* — кага башлау, шалтырый башлау; *колокол зазвонил* — кыңгырау кага башлады; *зазвонил телефон* — телефон шалтырый башлады.

**ЗАЗВУЧА'ТЬ** *сов.* — яңгырый башлау; *зазвучали голоса ребят* — балалар тавышы янгырый башлады.

**ЗАЗВЯ'КАТЬ** *сов. разг.* — шылтырый башлау, чылтырый (чалтырый) башлау.

**ЗАЗДРА'ВНЫЙ** *книж. устар.* — исәнлек теләп ...-ган; *заздравная песня* — исәнлек теләп җырланган җыр.

**ЗАЗЕВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — авыз ачып карап тору, авыз ачып карап бару, дөньясын онытып карап тору (карап бару); *он зазевался и ничего не заметил* — авызын ачып карап торып, бернәрсә дә сизми калды.

**ЗАЗЕЛЕНЕ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. *(начать зеленеть)* яшелләнә башлау, яшәрә башлау; *трава зазеленела* — үлән яшәрә башлады; 2. *(начать виднеться)* яшелләнеп күренә башлау.

**ЗАЗЕЛЕНИ'ТЬ** *сов. разг.* — яшелгә буяу, яшелгә пычрату.

**ЗАЗЕМЛИ'ТЬ** *сов. тех.* — җиргә тоташтыру.

**ЗАЗЕМЛИ'ТЬСЯ** *сов. тех.* — җир белән тоташу.

**ЗАЗЕМЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. заземлить.

**ЗАЗЕМЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. заземлиться.

**ЗАЗИМОВА'ТЬ** *сов.* — кышлап калу, кышка калу.

**ЗАЗИ'МОК** *м. обл.* — 1. *(первый снег)* беренче кар; 2. *(первые холода)* беренче суыклар; 3. беренче чана юлы; *поехать в район по зазимку* — районга беренче чана юлы белән китү.

**ЗАЗНАВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. зазнаться.

**ЗАЗНА'ЙСТВО** *ср. мн.* нет — масаю, минминлек, борын күтәрү.

**ЗАЗНА'МО** *нареч. обл.* — күрә торып, белә торып, ачыктан-ачык.

**ЗАЗНА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — масая башлау, масаеп китү, борын күтәрә башлау, әллә кем булып китү, кәпрәеп китү.

**ЗАЗНО'БА** *ж.* — 1. *разг. (возлюбленная)* җанкай, сөйгән яр, җанкай-җанаш; 2. *фольк. (любовь)* гыйшык.

**ЗАЗНОБИ'ТЬ** *сов.* — 1. *обл.* туңдыру, өшетү; 2. *безл.* туңдыра башлау, калтырата башлау; *больного зазнобило* — авыруны туңдыра башлады.

**ЗАЗО'Р** I *м. мн.* нет, *просторен.* — оят, хурлык, гарьлек.

**ЗАЗО'Р** II *м.* — ярык (ике әйбер арасында калган ачыклык).

**ЗАЗО'РНЫЙ** *разг.* — хурлыклы, хурланырлык, оят; *в этом нет ничего зазорного* — монда хурланырлык бернәрсә дә юк.

**ЗАЗРЕ'НИЕ:** без зазрения (совести) *разг.* — вөҗдансызлык белән, оятсыз рәвештә.

**ЗАЗРИ'ТЬ:** совесть зазрила *разг.* — вөҗданым кушмады, вөҗданым ирек бирмәде.

**ЗАЗУ'БРИВАТЬ** I *несов.* — к. зазубрить I.

**ЗАЗУ'БРИВАТЬ** II *несов.* — к. зазубрить II.

**ЗАЗУ'БРИВАТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. зазубриться; 2. *страд.* үтмәсләндерелү, йөзе кайтарылу.

**ЗАЗУ'БРИВАТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. зазубриться II; 2. *страд.* мәгънәсен анламыйча ятлану.

**ЗАЗУ'БРИНА** *ж.:* нож с зазубринами — кителеп беткән пычак, кыршалып беткән пычак (чалгы, бритва һ. б.).

**ЗАЗУ'БРИТЬ, ЗАЗУБРИ'ТЬ** I *сов.* — китеп бетерү, кыршалдыру; *зазубрить нож* — пычакны кыршалдыру.

**ЗАЗУБРИ'ТЬ** II *сов. разг.* — 1. (мәгънәсен анламыйча) ятлау; 2. *(начать зубрить)* (мәгънәсен анламыйча) ятлый башлау.

**ЗАЗУ'БРИТЬСЯ, ЗАЗУБРИ'ТЬСЯ** I *сов.* — кыршалу, кыршалып бетү, кителү, кителеп бетү.

**ЗАЗУБРИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — күп ятлаудан аңгыралану.

**ЗАЗЫВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. зазвать.

**ЗАЗЫВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — кыстап чакырып китерелү, кыстап чакырып кертелү.

**ЗАЗЫВНО'Й** *обл.* — чакыру ...-ы; *зазывные крики* — чакыру тавышлары.

**ЗАИГРА'ТЬ** *сов.* — 1. уйный башлау, уйнарга тотыну; *оркестр заиграл марш* — оркестр марш уйный башлады; 2. уйнап туздыру, уйный-уйный таушалдырып бетерү; *заиграть карты* — уйный-уйный кар-

таларны таушалдырып бетерү; 3. күп уйнап тәмен (кызыгын) җибәрү; *заиграть пьесу* — күп уйнап пьесаның кызыгын җибәрү; 4. уйный башлау, җемелди башлау, җем-җем итә башлау; *солнце заиграло на поверхности воды* — кояш су өстендә уйный башлады. ◇ Румянец заиграл на щеках — битләре алсуланып китте.

**ЗАИГРА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— уен белән мавыгып калу, уен белән мавыгып китү, бик озак уйнау; *дети заигрались* — балалар уенга мавыгып киттеләр.

**ЗАИ'ГРЫВАТЬ** I *несов.* — 1. шаярту; 2. *(заискивать)* ярарга тырышу, тәлинкә тоту, юмакайлану.

**ЗАИ'ГРЫВАТЬ** II *несов.*— к. заиграть 2, 3.

**ЗАИ'ГРЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. заиграться.

**ЗАИ'КА** *м.* и *ж.*— тотлыгып сөйләүче.

**ЗАИКА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. тотлыгу, тотлыгып сөйләү; 2. авыз ачу, телгә алу; *он и не заикался о поездке* — китү турында ул телгә дә алмады.

**ЗАИКНУ'ТЬСЯ** *сов. однокр.*— 1. тотлыгу; тотлыгып калу; 2. к. заикаться 2.

**ЗАИ'МКА** *ж.*— заимка, тарлау (1. элек: берәр кеше тарафыннан беренче тапкыр үзләштерелгән җир участогы; 2. Себердә кайбер кечкенә авылларның исеме).

**ЗАИМОДА'ВЕЦ** *м.*, **ЗАИМОДА'ВИЦА** *ж.* — бурычка бирүче, бурычка бирел торучы.

**ЗАИМОДА'ТЕЛЬ** *м. устар.* — к. заимодавец.

**ЗАИМООБРА'ЗНО** *нареч.* — көтәргә, бурычка, әҗәткә.

**ЗАИМООБРА'ЗНЫЙ** — көтәргә алынган (яки бирелгән), бурычка алынган (яки бирелгән), әҗәткә алынган (яки бирелгән).

**ЗАИ'МСТВОВАНИЕ** *ср.*— 1. к. заимствовать; 2. алынма; *в татарском языке много заимствований из русского языка* — татар телендә рус теленнән алынмалар күп.

**ЗАИ'МСТВОВАТЬ** *сов.* и *несов., книж.*— алу, үзләштерү.

**ЗАИ'МСТВОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд., книж.*— алыну, үзләштерелү.

**ЗАИ'НДЕВЕТЬ** *сов. разг.* — бәсләнү, сыкылану, бәс белән каплану, сыкы белән каплану.

**ЗАИНТЕРЕСО'ВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— кызыксыну.

**ЗАИНТЕРЕСОВА'ТЬ** *сов.*— 1. кызыксындыру; *его заинтересовала судьба ребёнка* — аны баланың язмышы кызыксындырды; 2. *разг.* кызыктыру, дәртләндерү.

**ЗАИНТЕРЕСОВА'ТЬСЯ** *сов.*—1. кызыксыну; 2. кызыгу, дәртләнү.

**ЗАИНТЕРЕСО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. заинтересовать.

**ЗАИНТЕРЕСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. заинтересоваться; 2. *страд.* — кызыксындырылу; кызыктырылу, дәртләндерелү.

**ЗАИНТРИГОВА'ТЬ** *сов.*— кызыксындыру.

**ЗАИ'СКИВАТЬ** *несов.*— ялагайлану, ярарга тырышу, тәлинкә тоту, куштанлану, яхшы атлы булырга тырышу.

**ЗАИ'СКИВАЮЩИЙ** — ялагайланучы, куштанланучы, тәлинкә тотучы, яхшы атлы булырга тырышучы; *заискивающий перед начальством чиновник* — начальниклар алдында ялагайланучы чиновник. ◇ Заискивающая улыбка — ярарга тырышып елмаю.

**ЗАИ'СКРИТЬСЯ** *сов.* — ялтырый башлау, ялтыр-йолтыр итә башлау, җем-җем итә башлау; *глаза заискрились* — күзләре ялтырый башлады.

**ЗА'ЙКА** *ж.*— куянкай.

**ЗА'ЙМИЩЕ** *ср.*— уйсулык, уйсу җир, су баса торган җир.

**ЗА'ЙМОВЫЙ** — заём ...-ы; *займовая кампания* — заём кампаниясе.

**ЗАЙМОДЕРЖА'ТЕЛЬ** *м.*— заём тотучы, заёмы булган.

**ЗАЙТИ'** *сов.*— 1. керү, кереп чыгу; *зайти в магазин* — магазинга кереп чыгу; *зайти к товарищу* — иптәшкә керү; 2. алырга керү, алып чыгарга керү; *зайти за товарищем* — иптәшне алырга керү; 3. керү, борылып керү; *зайти за забор* — койма артына борылып керү; 4. әйләнеп керү, барып керү; *зайти справа* — уң яктан әйләнеп керү; 5. бату, баю; *солнце зашло* — кояш баеды; *луна зашла* — ай батты; 6. *перен., книж. устар.* сүнү; *слава этого поэта никогда не зайдёт* — бу шагыйрьнең даны беркайчан да сүнмәс; 7. башлану, башланып китү; *разговор зашёл о колхозе* — сүз колхоз турында башланып китте.

**ЗА'ЙЧИК** *м. разг.*— 1. куянкай, кечкенә куян; 2. *(светлое пятно)* шәүлә, нур шәүләсе.

**ЗАЙЧИ'ХА** *ж.*— ана куян.

**ЗАЙЧО'НОК** *м.* (*мн.* зайчата) — куян баласы.

**ЗАКАБАЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. *(поработить)* кабалага төшерү, коллыкка төшерү, кол итү; 2. *перен. разг.* *(поставить в зависимость от себя)* үз кулына алу, үзенә буйсындыру.

**ЗАКАБАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— кабалага төшү, коллыкка төшү.

**ЗАКАБАЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. закабалить.

**ЗАКАБАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. закабалиться; 2. *страд.* кабалага төшерелү, коллыкка төшерелү.

**ЗАКАДЫ'ЧНЫЙ**: **закадычный друг (приятель)** *разг. фам.*— якын дус, җан дус, ахирәт дус.

**ЗАКА'З** I *м.*— заказ (1. берәр әйберне эшләргә бирү; 2. заказ буенча эшләнгән әйбер). ◇ Социальный заказ — иҗтимагый заказ (бер иҗтимагый сыйныфның ихтыяры, теләге).

**ЗАКА'З** II *м. устар.*— тыю.

**ЗАКАЗА'ТЬ** I *сов.*— заказ бирү, заказать итү.

**ЗАКАЗА'ТЬ** II *сов., устар. просторен.*— 1. *(запретить)* тыю; 2. *(приказать)* кушу, боеру. ◇ Все пути ему заказаны — аның өчен бөтен юллар ябык.

**ЗАКАЗНО'Й** — 1. заказ буенча эшләнгән; 2. заказной; *заказное письмо* — заказной хат.

**ЗАКА'ЗЧИК** *м.*, **ЗАКА'ЗЧИЦА** *ж.*—заказ бирүче.

**ЗАКА'ЗЫВАТЬ** I *несов.*— к. заказать I.

**ЗАКА'ЗЫВАТЬ** II *несов. устар., просторечь.*— к. заказать II.

**ЗАКА'ЗЫВАТЬСЯ** I *несов. страд.*— заказ бирелү, заказать ителү.

**ЗАКА'ЗЫВАТЬСЯ** II *несов. страд., устар. простореч.*— 1. тыелу; 2. боерылу.

**ЗАКА'ИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. закаяться.

**ЗАКА'Л** *м. мн.* нет — 1. (*действие*) сугару, чыныктыру; *закал стали* — корычны сугару; 2. сугарылыш; *сталь крепкого закала* — нык сугарылышлы корыч; 3. *разг.* (*твёрдость характера*) ныклык, чыныкканлык; 4. кайрак; *хлеб с закалом* — кайраклы икмәк. ◇ **Человек старого закала** — 1. иске тәрбия алган кеше; 2. иске гореф-гадәтләрне саклаучы кеше.

**ЗАКАЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — чыныкканлык.

**ЗАКАЛЁННЫЙ** — 1. *тех.* сугарылган, чыныктырылган; *закалённая сталь* — сугарылган корыч; 2. *перен.* чыныккан, ныгыган; *закалённая в боях армия* — сугышларда чыныккан армия; 3. чыныккан, физик яктан таза; *закалённый ребёнок* — физик яктан таза бала.

**ЗАКА'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. закалить 1.

**ЗАКА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. закалиться; 2. *страд. тех.* чыныктырылу, сугарылу.

**ЗАКАЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. *тех.* сугару, чыныктыру; *закалить сталь* — корыч чыныктыру; 2. *перен.* чыныктыру, ныгыту; *сама жизнь закалила его* — аны тормыш үзе чыныктырган.

**ЗАКАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *тех.* чыныгу; *сталь закалилась* — корыч чыныкты; 2. *перен.* чыныгу, ныгу; *армия закалилась в боях* — армия сугышларда чыныкты.

**ЗАКА'ЛЫВАТЬ** *несов.*— к. заколоть 1, 2.

**ЗАКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. заколоться; 2. *страд.* чәнчеп үтерелү, суелу; кадап куелу, чәнчеп куелу; корбанга чалыну.

**ЗАКАЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. закалить.

**ЗАКАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. закалиться; 2. *страд.* чыныктырылу.

**ЗАКАМЕНЕ'ТЬ** *сов. разг.* — ташка әйләнү, таш кебек кату.

**ЗАКА'НЧИВАТЬ** *несов.*— к. закончить.

**ЗАКА'НЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. закончиться; 2. *страд.* бетерелү, тәгәлләнү, тәмамлану.

**ЗАКА'ПАТЬ** *сов. разг.*— 1. тама башлау; *слёзы закапали из глаз* — күзләрдән яшь тама башлады; тамчылый башлау, төшә (төшкәли) башлау, тама (тамгалый) башлау; *дождь закапал* — яңгыр тамгалый башлады; 2. чәчрәтеп пычрату; чәчрәтеп пычратып бетерү; *закапать себе платье* — чәчрәтеп күлмәкне пычратып бетерү.

**ЗАКАПРИ'ЗНИЧАТЬ** *сов. разг.* — көйсезләнә башлау, үзсүзләнә башлау; кәҗәләнә башлау; *ребёнок закапризничал* — бала көйсезләнә башлады.

**ЗАКА'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. закопать 2.

**ЗАКА'ПЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. закопаться 2; 2. *страд.* күмелү, күмеп куелу.

**ЗАКА'РМЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. закормить.

**ЗАКАРТА'ВИТЬ** *сов. разг.*— 1. сакауланып сөйли башлау; 2. сакаулана башлау, сакауланып калу (элек сакау булмаган кеше турында).

**ЗАКА'Т** *м.*— 1. баю, бату, баеш; *закат солнца* — кояш баюы; кояш баешы; 2. (*вечерняя заря*) шәфәкъ; 3. *перен.* (*конец*) сүнү, бетү, һәлакәт; *жизнь его близилась к закату* — аның гомере бетүгә якынаеп килә иде. ◇ **На закате дней** *книж.*— картлыгында, карт көнендә, гомеренең соңгы көннәрендә.

**ЗАКАТА'ТЬ** *сов.*— 1. (*начать катать*) йөртә башлау (утыртып), тәгәрәтә башлау; эвәли башлау; 2. төрү, төреп кую, чорнау, чорнап кую; *закатать в полотенце* — сөлге белән чорнап кую; 3. бастыру, тигезләү; *закатать дорожку* — юлны тигезләү; 4. *перен. фам.* (*загнать, сослать*) җибәрү, озату, олактыру.

**ЗАКАТИ'ТЬ** *сов. разг.*— тартып кертү; тәгәрәтеп кертү; *закатить телегу во двор* — арбаны ишек алдына тартып кертү; *закатить мяч под диван* — тупны диван астына тәгәрәтеп кертү. ◇ **Закатить пощёчину** *простореч.*— яңагына кундыру, яңагына салып җибәрү. **Закатить истерику** *простореч. фам.*— ярсып елый башлау. **Закатить глаза** — күзне акайту. **Закатить пир горой** *простореч. фам.*— зур кәеф-сафа мәҗлесе үткәрү.

**ЗАКАТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. тәгәрәп керү; *мяч закатился под диван* — туп диван астына тәгәрәп керде; 2. баю, бату; *солнце закатилось* — кояш баеды; *закатилась луна* — ай батты; 3. *перен.* сүнү; 4. китү, китеп бару; *закатиться за город* — шәһәр читенә китү. ◇ **Закатиться смехом** — эче катып көлә башлау.

**ЗАКА'ТНЫЙ** — 1. шәфәкъ ...-ы; *закатные лучи* — шәфәкъ нурлары; 2. кояш бату ...-ы, кояш баю ...-ы; *закатный час* — кояш баю сәгате.

**ЗАКА'ТЫВАТЬ** *несов.*— 1. к. закатать 2, 3, 4; 2. к. закатить.

**ЗАКА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. закатиться; 2. *страд.* төрелү, чорналу, уралу; тәгәрәтеп тигезләнү, бастырылу (каток белән); тартып кертелү; тәгәрәтеп кертелү.

**ЗАКАЧА'ТЬ** *сов.*— 1. селкетә башлау, селки башлау; *сильный ветер закачал деревья* — көчле җил агачларны селкетә башлады; *закачать головой* — башны селки башлау; (*о люльке*) тирбәтә башлау; (*на качелях*) атындыра башлау; 2. (*качая утомить*) тирбәтеп арыту, тирбәтеп башны әйләндерү; 3. *безл.* баш әйләнә башлау, косасы килә башлау; *меня закачало на*

*пароходе* — пароходта минем башым әйләнә башлады.

**ЗАКАЧА'ТЬСЯ** *сов.* — тирбәлә башлау, селкенә башлау; чайкала башлау; *лодка закачалась* — көймә чайкала башлады.

**ЗАКА'ШИВАТЬ** *несов. обл.* — к. закосить 2.

**ЗАКА'ШЛЯТЬ** *сов. разг.* — йөткерә башлау, йөткерергә тотыну, ютәлли башлау.

**ЗАКА'ШЛЯТЬСЯ** *сов. разг.* — буылып йөткерә башлау.

**ЗАКА'ЯТЬСЯ** *сов. разг.* — сүз бирү, тәүбә итү; *закаялся курить* — тәмәке тартмаска сүз бирдем.

**ЗАКВА'СИТЬ** *сов.* — ачыту, оету; *заквасить тесто* — камыр ачыту; *заквасить молоко* — катык оету.

**ЗАКВА'СКА** *ж. мн.* нет — 1. к. заквасить; 2. оеткы (катык өчен); чүпрә, ачыткы, баш, камыр башы (күәс төбендә калдырылган камыр); *положить закваску в молоко* — сөткә оеткы салу; *положить закваску в тесто* — камырга чүпрә (камыр башы) салу. ◇ **Человек хорошей закваски** — яхшы семьядан чыккан кеше.

**ЗАКВА'ШИВАТЬ** *несов.* — к. заквасить.

**ЗАКВА'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — ачытылу, оетылу.

**ЗАКИВА'ТЬ** *сов. разг.* — (башны) селки башлау.

**ЗАКИДА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. ыргыта башлау; *закидать камнями* — таш ыргыта башлау; 2. ыргытып тутыру, күмү, күмеп ташлау; *закидать яму* — чокырны күмү. ◇ **Шапками закидаем** *разг. фам.* — бүрек белән бәреп егарбыз (дошманны җиңүне бик ансатка санау).

**ЗАКИ'ДЫВАТЬ** *несов.* — 1. к. закидать 2; 2. к. закинуть.

**ЗАКИ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. закинуться; 2. *страд.* ыргытып тутырылу, күмелү; ыргытылу, еракка ыргытылу, салыну, еракка салыну.

**ЗАКИ'НУТЬ** *сов.* — 1. к. забросить 1, 2; 2. салу; *закинуть ружьё за спину* — мылтыкны аркага салу. ◇ **Закинуть голову кверху** — башны югары күтәрү; башны артка ташлау. **Закинуть словечко (или слово)** *разг. фам.* — җае килгәндә сүз кушу, сүз уңаенда әйтү. **Закинуть удочку** *перен. разг.* — кылын тартып карау.

**ЗАКИ'НУТЬСЯ** *сов.* — 1. ташлану, артка ташлану; *голова закинулась* — башы артка ташланган; 2. (*о лошади*) буйлау.

**ЗАКИПА'ТЬ** *несов.* — к. закипеть.

**ЗАКИПЕ'ТЬ** *сов.* — кайный башлау; *вода закипела* — су кайный башлады; *работа закипела* — эш кайный башлады.

**ЗАКИСА'ТЬ** *несов.* — к. закиснуть.

**ЗАКИ'СНУТЬ** *сов.* — 1. әчү, ою; *тесто закисло* — камыр әчеде; 2. *перен. разг.* сүлпәнләнү, җебү, изрәп төшү; *он устал и совсем закис* — ул арыган һәм бөтенләй изрәп төшкән.

**ЗАКЛА'Д** *м. разг.* — заклад (бурычка акча алганда яки бәхәсләшкәндә куела торган әйбер).

**ЗАКЛА'ДКА** *ж. мн* нет — 1. к. заложить; 2. билге (китапка салына торган); 3. *обл.* (*засов*) аркылы агач.

**ЗАКЛАДНО'Й** — 1. нигез ...-ы, нигез салуга китә торган; *закладной камень* — нигез ташы; 2. *канц.* заклад ...-ы; *закладная квитанция* — заклад квитанциясе.

**ЗАКЛА'ДЧИК** *м.*, **ЗАКЛА'ДЧИЦА** *ж.* — закладка салучы.

**ЗАКЛА'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. заложить.

**ЗАКЛА'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. куелу; 2. салыну; салына башлау; 3. тутырылу, тутырып бетерелү, томалану, каплану, каплап куелу; 4. җигелү; 5. билге салып куелу.

**ЗАКЛА'ТЬ** *сов., книж. устар.* — корбанга чалу.

**ЗАКЛЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. (*начать клевать*) чиертә башлау, каба башлау; 2. чукып үтерү; *вороны заклевали голубя* — каргалар күгәрченне чукып үтергәннәр; 3. *перен. разг.* (*затравить*) кыерсыту, талау, кагу (кешене).

**ЗАКЛЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. заклевать 2.

**ЗАКЛЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. заклеить.

**ЗАКЛЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. заклеиться; 2. *страд.* ябыштырылу, ябыштырылып куелу.

**ЗАКЛЕИ'ТЬ** *сов.* — ябыштыру, ябыштырып кую; *заклеить конверт* — конвертны ябыштырып кую.

**ЗАКЛЕИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ябышу.

**ЗАКЛЕ'ЙКА** *ж.* — 1. к. заклеить; 2. (*клейкий материал*) ябыштыру материалы.

**ЗАКЛЕЙМИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*поставить клеймо*) келәймә сугу, келәймәләү, тамга салу; 2. *перен.* хурлык тамгасы салу, тирән нәфрәт белдерү; *заклеймить изменников революции* — революциягә хыянәт итүчеләргә хурлык тамгасы салу.

**ЗАКЛЕПА'ТЬ** *сов. тех.* — заклёпка белән беркетү, беркетеп кую.

**ЗАКЛЁПКА** *ж. тех.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. заклепать; 2. заклёпка.

**ЗАКЛЁПЫВАТЬ** *несов. тех.* — к. заклепать.

**ЗАКЛЁПЫВАТЬСЯ** *несов. страд., тех.* — заклёпка белән беркетелү, беркетеп куелу.

**ЗАКЛИ'КАТЬ** *сов., разг. обл.* — 1. кычкыра башлау, чакыра башлау; (*о гусях*) гаңгылдый башлау; 2. к. зазвать.

**ЗАКЛИКА'ТЬ** *несов., разг. обл.* — к. зазвать.

**ЗАКЛИНА'НИЕ** *ср. книж.* — 1. к. заклинать; 2. әфсен.

**ЗАКЛИНА'ТЕЛЬ** *м.*, **ЗАКЛИНА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — әфсенләүче, өшкерүче.

**ЗАКЛИНА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. (*заколдовывать*) сихерләү, әфсенләү; 2. (*умолять*) ялварып сорау, ялвару.

**ЗАКЛИ'НИВАТЬ** *несов.* — к. заклинить.

**ЗАКЛИ'НИТЬ** *сов.* — чөй кагу; *заклинить бревно* — бүрәнәгә чөй кагу.

**ЗАКЛОКОТА'ТЬ** *сов. разг.* — бытырдый башлау, бытырдап кайный башлау.

**ЗАКЛУБИ'ТЬ** *сов.*— өермәләндерә башлау, бөтереп һавага күтәрү; *ветер заклубил пыль на дороге* — җил юлдагы тузанны бөтереп һавага күтәрде.

**ЗАКЛУБИ'ТЬСЯ** *сов.*— бөтерелеп һавага күтәрелә башлау; *пыль заклубилась от ветра* — тузан җилдән бөтерелеп һавага күтәрелә башлады.

**ЗАКЛЮЧА'ТЬ** *несов.*— к. заключить. ◇ **Заключает в себе** — эченә ала.

**ЗАКЛЮЧА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. гыйбарәт булу, тору; *дело заключается в следующем* ...— эш шуннан гыйбарәт ...; 2. *страд.* (*в тюрьму*) ябылу, утыртылу; 3. *страд.* (*заканчиваться*) тәмамлану, тәмам ителү, төгәлләнү; 4. *страд.* (*о договорах* и т. д.) төзелү.

**ЗАКЛЮЧЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. к. заключить; 2. (*место заключения*) төрмә; 3. (*вывод*) нәтиҗә, йомгак; 4. (*оценка специалиста*) заключение; 5. (*заключительная часть*) соңгы өлеше, йомгак өлеше. ◇ **В заключение** — сүзнең ахырында, соңгы сүз итеп.

**ЗАКЛЮЧЁННЫЙ** *книж.*— 1. ябылган, ябып куелган; 2. төзелгән (договор); 3. эчендә булган; ...-дән аңлашылган; *смысл, заключённый в твоих словах, сводится к следующему* ...— синең сүзләреңнән аңлашылган мәгънә түбәндәгегә кайтып кала...; 4. *в знач. сущ.*— кулга алынган кеше, тоткын, тоткындагы кеше; *политические заключённые* — политик тоткыннар.

**ЗАКЛЮЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— ахыргы, соңгы; тәмамлау ...-ы; йомгаклау ...-ы; *заключительные слова* — соңгы сүзләр (докладчының); *заключительный баланс* — йомгаклау балансы.

**ЗАКЛЮЧИ'ТЬ** *сов.*— 1. (*в тюрьму*) ябу, ябып кую, утырту; 2. нәтиҗә ясау, нәтиҗә чыгару; нәтиҗәгә килү; *из его слов я заключил, что* ...— аның сүзләреннән мин ... дигән нәтиҗәгә килдем; 3. тәмамлау, бетерү, төгәлләү; *заключить доклад приветствиями* — докладны котлау сүзләре белән бетерү; 4. төзү; *заключить договор* — договор төзү. ◇ **Заключить брак** — өйләнешү. **Заключить в объятия** — кочакка алу, куенга алу, кочаклау. **Заключить в скопки** — җәяләр эченә алу.

**ЗАКЛЯ'СТЬ** *сов. книж.*— к. заклинать 1.

**ЗАКЛЯ'СТЬСЯ** *сов.*—1. *книж. устар.* (*заречься*) тәүбә итү, сүз бирү, ант итү; 2. *разг.* (*начать клясться*) ант итә башлау, тәүбә итә башлау.

**ЗАКЛЯ'ТИЕ** *ср. книж. устар.*— 1. к. заклинание; 2. (*клятва, зарок*) тәүбә, ант итү, сүз бирү.

**ЗАКЛЯ'ТЫЙ** — 1. мәңге, гомерлек; *заклятый враг* — гомерлек дошман; 2. *разг. устар.* (*рьяный*) хирес; *заклятый картёжник* — карта уенына хирес кеше; 3. *книж.* сихерле, сихерләнгән; *заклятый дом* — сихерләнгән өй.

**ЗАКОВА'ТЬ** *сов.*— 1. (*надеть кандалы*) богаулау, богау кидерү; 2. *поэт.* туңдыру, катыру; *мороз заковал реку* — салкыннар елганы туңдырды; 3. *книж. устар.* тоткарлау, томалау; *заковать мысли* — фикерләрне тоткарлау; 4. (*начать ковать*) чүки башлау; 5. (*ковкой повредить*) дагалап бозу.

**ЗАКО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. заковать 1, 2, 3.

**ЗАКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— богаулану.

**ЗАКОВЫ'КА** *ж.*, **ЗАКОВЫ'РКА** *ж. простореч. обл.*— к. заковычка.

**ЗАКОВЫЛЯ'ТЬ** *сов. разг.*— аксаклап китеп бару, тыйтаклап китеп бару; көч-хәл белән китеп бару.

**ЗАКОВЫ'РИСТЫЙ** *разг.*— четрекле, хикмәтле, әкәмәт; *заковыристая задача* — четрекле мәсьәлә; *заковыристый парень* — хикмәтле (әкәмәт) егет.

**ЗАКОВЫ'ЧКА** *ж. простореч.*— 1. (*препятствие*) — комачау, тоткарлык; 2. (*хитрость*) хәйлә, читләтеп сөйләү.

**ЗАКОЛА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. заколотить 1, 2, 3.

**ЗАКОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— к. заколотиться 1.

**ЗАКОЛДО'ВАННЫЙ** — сихерле, тылсымлы, әфсенле; сихерләнгән, әфсенләнгән. ◇ **Заколдованный круг** *перен. книж.*— сихерле түгәрәк (ерып чыга алмаслык хәл).

**ЗАКОЛДОВА'ТЬ** *сов.*— сихерләү, үзенә карату.

**ЗАКОЛДО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. заколдовать.

**ЗАКОЛДО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— сихерләнү.

**ЗАКОЛЕБА'ТЬ** *сов.*— селкетә башлау, тирбәтә башлау.

**ЗАКОЛЕБА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. селкенә башлау, тирбәлә башлау, чайкала башлау; *ветви заколебались* — ботаклар селкенә башлады; 2. *перен.* икеләнә башлау; *он заколебался* — ул икеләнә башлады.

**ЗАКОЛО'ДИТЬ** *сов. обл.*— тоткарлык булу; *зачем он не идёт? не заколодило ли ему?*— нигә ул килми? берәр тоткарлык булмадымы икән аңа?

**ЗАКОЛОСИ'ТЬСЯ** *сов.*— баш кыса башлау, баш чыгара башлау, башаклана башлау.

**ЗАКОЛОТИ'ТЬ** *сов.*— 1. кагып кую, кадаклап кую; *заколотить ящик гвоздями* — ящикны кадаклап кую; 2. кагу, кагып кертү; *заколотить гвоздь в стену* — стенага кадак кагып кертү; 3. *простореч.* (*забить до смерти*) үтергәнче кыйнау, тукмаклау; 4. шакылдата башлау, дөбердәтә башлау; *они заколотили в дверь* — алар ишекне шакылдата башладылар.

**ЗАКОЛОТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. кадаклану, кадаклап куелу; *окна заколотились досками* — тәрәзәләр такталар белән кадакланды; 2. кагылу; *кол заколотился в землю* — казык җиргә кагылды; 3. тибә башлау; *сердце заколотилось* — йөрәк тибә башлады.

**ЗАКОЛО'ТЬ** *сов.*— 1. чәнчеп үтерү; *заколоть штыком* — штык белән чәнчеп

үтерү; **2.** (*зарезать*) сую, чалу; **2.** *разг.* (*приколоть*) чәнчеп кую, кадап кую; **4.** *безл.* чәнчи башлау, чәнчешә башлау; *опять закололо в груди* — күкрәгем тагын чәнчешә башлады.

**ЗАКОЛО'ТЬСЯ** *сов. разг.* — чәнчелеп үлү.

**ЗАКОЛОШМА'ТИТЬ** *сов. обл.* — **1.** тукмау, кыйнау; **2.** тукмый башлау.

**ЗАКОЛЫХА'ТЬ** *сов. разг.* — тирбәтә башлау; дулкынландыра башлау; җилфердәтә башлау; чайкалдыра башлау; *вода заколыхала лодку* — су көймәне чайкалдыра башлады.

**ЗАКОЛЫХА'ТЬСЯ** *сов.* — селкенә башлау, тирбәлә башлау; дулкынлана башлау; чайкала башлау; җилферди башлау; *хлеба заколыхались* — ашлыклар дулкынлана башлады; *лодки заколыхались* — көймәләр чайкала башлады; *заколыхались знамёна* — байраклар җилферди башлады.

**ЗАКО'Н** *м.* — **1.** закон; **2.** гадәт; *законы гостеприимства* — кунакчыллык гадәтләре; **3.** *обл. устар.* (*брак*) никах. ◇ **Драконовы законы** — Дракон законнары, каты законнар, рәхимсез законнар.

**ЗАКО'ННИК** *м.*, **ЗАКО'ННИЦА** *ж. разг.* — **1.** законччы, законнар белгече; **2.** законны җиренә җиткерүче.

**ЗАКО'ННО** *нареч.* — законлы, урынлы, законлы рәвештә.

**ЗАКО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — законлылык, законлы булу.

**ЗАКО'ННЫЙ** — **1.** законлы, законга каршы килми торган, законга туры килә торган, закон ...-ы; *на законном основании* — закон нигезендә; **2.** урынлы, хаклы; *законное требование* — урынлы таләп.

**ЗАКОНОВЕ'Д** *м.* — **1.** *книж. устар.* законччы, законнар белгече, юрист; **2.** *дореволюц.* законнар белеме укытучысы.

**ЗАКОНОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *дореволюц.* — законнар белеме.

**ЗАКОНОДА'ТЕЛЬ** *м.*, **ЗАКОНОДА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — **1** (*устанавливающий законы*) законнар чыгаручы; **2.** *перен.* яңалык кертүче; гадәт (гореф) урнаштыручы; *законодатель мод* — модалар кертүче.

**ЗАКОНОДА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — законнар чыгара торган; законнар чыгаруга хокуклы; *законодательная власть* — законнар чыгара торган (чыгаруга хокуклы) власть.

**ЗАКОНОДА'ТЕЛЬСТВО** *ср. книж. юр.* — **1.** *только ед.* законнар төзү, законнар чыгару; *комиссия по законодательству* — законнар төзү комиссиясе; **2.** законнар; *законодательство о труде* — хезмәт турындагы законнар; *советское законодательство* — совет законнары.

**ЗАКОНОМЕ'РНО** *нареч. книж.* — закончалы рәвештә; *закономерно развиваться* — закончалы рәвештә үсү.

**ЗАКОНОМЕ'РНОСТЬ** *ж. книж.* — закончалык; *закономерность развития* — үсешнең закончалыгы.

**ЗАКОНОМЕ'РНЫЙ** *книж.* — закончa; *закономерное явление* — закончa күренеш.

**ЗАКОНОПА'ТИТЬ** *сов.* — **1.** мүкләү, конопать итү; **2.** *перен. разг.* (*поместить в тесное помещение*) шыплап тутыру, тыгызлап тутыру; **3.** *перен. разг.* (*сослать*) олактыру, еракка сөрү.

**ЗАКОНОПА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. законопатить.

**ЗАКОНОПА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — конопать ителү, мүкләнү, мүк тутырылу.

**ЗАКОНОПОЛОЖЕ'НИЕ** *ср. книж.* — законоположение, закон карары; (аерым мәсьәләләргә караган) законнар; *по существующим законоположениям* — яшәп килә торган законнар буенча.

**ЗАКОНОПРОЕ'КТ** *м.* — закон проекты.

**ЗАКОНОСОВЕЩА'ТЕЛЬНЫЙ** *юр.* — закон проектларын тикшерү ...-ы; *законосовещательный орган* — закон проектларын тикшерү органы.

**ЗАКОНСЕРВИ'РОВАТЬ** *сов.* — к. консервировать.

**ЗАКОНСЕРВИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* — к. консервироваться 1.

**ЗАКОНСПИРИ'РОВАТЬ** *сов.* — к. конспирировать.

**ЗАКОНТРАКТОВА'ТЬ** *сов.* — контрактацияләү, контрактация договоры төзү.

**ЗАКОНТРАКТОВА'ТЬСЯ** *сов.* — контрактацияләнү, контракт буенча эш алу.

**ЗАКОНТРАКТО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. законтрактовать.

**ЗАКОНТРАКТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. законтрактоваться.

**ЗАКО'НТУРНЫЙ** — контурдан тыш, тирәли; *законтурное обводнение* — тирәли суландыру (нефть чыгару эшендә).

**ЗАКОНФУ'ЗИТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — оялу, оялып китү.

**ЗАКО'НЧЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — **1.** тәмамланганлык, төгәлләнгәнлек; **2.** тулылык, бөтенлек, житешлек; *законченность поэтического образа* — поэтик образның тулылыгы.

**ЗАКО'НЧЕННЫЙ** — **1.** тәмамланган, төгәлләнгән, эшләнеп беткән; *законченная работа* — эшләнеп беткән эш; **2.** тулы, бөтен, һәр яктан житеш; тәмамланган; *законченная мысль* — тулы фикер; *законченное высшее образование* — тәмамланган югары белем; **3.** җитлеккән, үсеп җиткән; *законченный художник* — үсеп җиткән художник. ◇ **Законченный дурак** — шыр тиле, чиктән ашкан тиле. **Законченный негодяй** — чиктән тыш кабахәт кеше.

**ЗАКО'НЧИТЬ** *сов.* — бетерү, тәмамлау, төгәлләү; йомгаклау.

**ЗАКО'НЧИТЬСЯ** *сов.* — бетү, тәмамлану, төгәлләнү; *рабочий день закончился* — эш көне бетте.

**ЗАКОПА'ТЬ** *сов.* — **1.** (*начать копать*) казый башлау; **2.** күмү, күмеп кую; *закопать в землю* — җиргә күмеп кую; *закопать яму* — чокырны күмеп кую.

**ЗАКОПА'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** (*начать копаться*) казына башлау; **2.** күмелү; *дети закопались по колено в песок* — балалар тезләренә чаклы комга күмелгәннәр.

**ЗАКОПОШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. кайнаша башлау, мыж килә башлау; *муравьи закопошились* — кырмыскалар мыж килә башлады; 2. маташа башлау, казына башлау.

**ЗАКОПТЕ'ТЬ** *сов. устар.*— к. закоптиться 2.

**ЗАКОПТИ'ТЬ** *сов.*— 1. каклау, каклап хәзерләү, ыслау; *закоптить рыбу* — балык каклау; 2. корымлау, корым белән каплау; *закоптить стекло* — пыяланы корымлау; 3. төти башлау; *лампа опять закоптила* — лампа тагын төти башлады; 4. *(начать копчение)* каклый башлау.

**ЗАКОПТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. каклану, ыслану; 2. корым белән каплану, корымланып бетү; *потолок закоптился* — түшәм корымланып беткән.

**ЗАКОРЕНЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. төпләнгәнлек, тамыр җәйгәнлек; нык урнашканлык, канына сеңгәнлек; 2. *перен.* катып калганлык, ашып узганлык, төзәлмәслек хәлгә килү.

**ЗАКОРЕНЕ'ЛЫЙ** — 1. төпләнгән, тамыр җәйгән, нык урнашкан, канына сеңгән; *закоренелые привычки* — нык урнашкан гореф-гадәтләр; 2. катып калган, ашып узган, төзәлмәслек; *закоренелый бюрократ* — төзәлмәс бюрократ (ата бюрократ).

**ЗАКОРЕНЕ'ТЬ** *сов. книж. устар.*— 1. *(укрепиться)* ныгу, тамыр җәю, гадәткә кереп китү; 2. тулысынча буйсыну, бирелү; *закоренеть в дурных привычках* — начар гадәтләргә бирелү.

**ЗАКО'РКИ: на закорки, на закорках** *простореч.*— җилкәгә; *сесть на закорки* — җилкәгә утыру; *нести на закорках* — җилкәгә атландырып алып бару.

**ЗАКОРМИ'ТЬ** *сов. разг.*— артык ашату, чамадан тыш ашату, үтләгәнче ашату.

**ЗАКОРО'БИТЬ** *сов. безл. простореч.*— 1. калҗая башлау; 2. *перен.* начар тәэсир калдыру; кәефне җибәрү; күңелне болгату; *меня закоробило от этой шутки* — бу шаярудан минем күңелем болгана башлады.

**ЗАКОРПЕ'ТЬ** *сов. разг.*— бирелеп эшли башлау, тырышып эшли башлау.

**ЗАКОРУ'ЗЛЫЙ** *обл.*— к. заскорузлый.

**ЗАКОРЮ'КА** *ж. разг. обл.*— к. закорючка.

**ЗАКОРЮ'ЧКА** *ж. разг.*— 1. ыргак, эләктергеч; 2. *перен. обл. (помеха, препятствие)* тоткарлык, комачау. ◇ **Писать с закорючками** —бормалы-сырмалы итеп язу.

**ЗАКОСИ'ТЬ** *сов. обл.*— 1. *(начать косить)* чаба башлау; 2. кереп чабу, чабып алу; *первая бригада закосила участок второй бригады* — беренче бригада икенче бригада участогына кереп чапкан.

**ЗАКОСНЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— катып калганлык, наданлык, культурасызлык; *раньше крестьяне находились в закоснелости* — элек крестьяннар наданлыкта яшиләр иде.

**ЗАКОСНЕ'ЛЫЙ** *книж.*— катып калган, төзәлмәс, ...-га чумган, надан, культурасыз; *закоснелое невежество* — катып калган тупаслык (культурасызлык).

**ЗАКОСНЕ'ТЬ** *сов. книж.*— катып калу, батып калу; *закоснеть в невежестве* — культурасызлыкка батып калу, тупаслыкта катып калу.

**ЗАКОСТЕНЕВА'ТЬ** *несов. редко*— к. закостенеть.

**ЗАКОСТЕНЕ'ЛЫЙ** *книж.*— каткан, катып калган; *закостенелые руки* — каткан куллар.

**ЗАКОСТЕНЕ'ТЬ** *сов.*— кату, катып калу; *пальцы закостенели* — бармакларым катты; *он закостенел от ужаса* — ул куркудан катып калды.

**ЗАКОСТЫЛЯ'ТЬ** *сов. простореч.*— култык таякларына таянып китеп бару; аксыйаксый китеп бару.

**ЗАКОУ'ЛОК** *м. разг.*— 1. *(глухой переулок)* караңгы тыкрык; 2. *разг.* караңгы почмак, аулак почмак; *обыскать все закоулки* — бөтен караңгы почмакларны актарып чыгу.

**ЗАКОЧЕНЕ'ТЬ** *сов.*— к. коченеть.

**ЗАКРА'ДЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. закрасться.

**ЗАКРА'ИВАТЬ** *несов.*— к. закроить.

**ЗАКРА'ИНА** *ж.*— 1. яр буе суы (кар эрүдән елгада боз белән яр арасында җыелган су); 2. *обл.* яр буе бозы, яр буендагы боз; 3. *обл.* кырый, чит.

**ЗАКРА'ПАТЬ** *сов. разг.*— 1. сибәли башлау; *дождик закрапал* — яңгыр сибәли башлады; 2. бөркеп чуарлау.

**ЗАКРА'ПЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. закрапать 2.

**ЗАКРА'СИТЬ** *сов.*— 1. буяу, буяп кую, буяп каплау; *закрасить пятна* — тапларны буяп каплау; 2. буйый башлау.

**ЗАКРА'СИТЬСЯ** *сов. разг.*— буялу, буяу белән каплану; *все пятна закрасились* — барлык таплар буяу белән капландылар.

**ЗАКРАСНЕ'ТЬ** *сов.* — 1. күренә башлау (кызыл әйбер турында); *издали закраснели крыши домов* — еракта өй түбәләре кызарып күренә башлады; 2. кызара башлау; *заря закраснела* — таң кызара башлады.

**ЗАКРАСНЕ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. күренә башлау (кызыл әйбер турында); *вдали закраснелись фабричные трубы* — еракта фабрика трубалары кызарып күренә башлады; 2. кызарыну, кызарып китү; *закраснеться от стыда* — оялудан кызарып китү.

**ЗАКРА'СТЬСЯ** *сов.*—1. *(тайно забраться)* посып керү, качып керү, яшеренеп керү; 2. *перен.* туу; *в мою душу закралось сомнение* — минем күңелемдә шик туды.

**ЗАКРА'ШИВАТЬ** *несов.*— к. закрасить 1.

**ЗАКРА'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — к. закраситься.

**ЗАКРЕ'ПА** *ж. спец.*— беркеткеч, ныгыткыч.

**ЗАКРЕПИ'ТЕЛЬ** *м. спец.* — ныгыткыч, фиксаж, фиксатив.

**ЗАКРЕПИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* —ныгыта торган, беркетә торган, беркетү ...-ы; *закрепительное средство* — ныгыта торган средство; *закрепительный талон* — беркетү талоны.

**ЗАКРЕПИ'ТЬ** *сов.*— 1. ныгыту, ныгытып кую; беркетү, беркетеп кую; *закрепить гвоздем* — кадак белән ныгыту; 2. *перен.* ныгыту; *закрепить завоевания* — казанышларны ныгыту; 3. *фото.* фиксажлау; *закрепить снимок* — рәсемне фиксажлау; 4. беркетү; *закрепить трактор за трактористом* — тракторны тракторчыга беркетү; 5. *мед.* ныгыту, нормаль хәлгә китерү; *закрепить желудок* — ашказанын ныгыту.

**ЗАКРЕПИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. беркетелү, беркетеп куелу; *трактористы закрепились за тракторами* — тракторчылар тракторларга беркетелделәр; 2. нык урнашу; *закрепиться на позиции* — позициядә нык урнашу.

**ЗАКРЕПЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. закрепить.

**ЗАКРЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. закрепиться; 2. *страд.* ныгытылу.

**ЗАКРЕПОСТИ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. *(сделать крепостным)* крепостнойлыкка төшерү; 2. *перен. (поработить)* кол итү, коллыкка төшерү, кабалага төшерү.

**ЗАКРЕПОСТИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— коллыкка төшү, кабалага керү.

**ЗАКРЕПОЩА'ТЬ** *несов.*— к. закрепостить.

**ЗАКРЕПОЩА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. закрепоститься; 2. *страд.* коллыкка төшерелү, кабалага төшерелү; кол ителү.

**ЗАКРИВИ'ТЬ** *сов. разг.* — бөгеп кую, кәкрәйтү; *закривить проволоку* — тимер чыбыкны бөгеп кую. ◇ **Закривить душой** — кыекка суктыра башлау, ялганлый башлау.

**ЗАКРИВИ'ТЬСЯ** *сов.*— бөгелү, кәкрәю.

**ЗАКРИВЛЯ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— кылана башлау, боргалана-сыргалана башлау, маймыллана башлау.

**ЗАКРИСТАЛЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов. спец.*— кристаллану, кристаллга әверелү; *раствор закристаллизовался* — эремә кристалланган.

**ЗАКРИЧА'ТЬ** *сов.*— 1. кычкырып җибәрү; *закричать от боли* — авыртудан кычкырып җибәрү; 2. *(начать кричать)* кычкыра башлау.

**ЗАКРО'ЕЧНЫЙ** — кием кисә торган, кием кисү ...-ы; *закроечный цех* — кием кисү цехы.

**ЗАКРОИ'ТЬ** *сов.*— 1. *порт. сапож.* кисү; 2. *столяр.* ырмаулау, уеп алу.

**ЗАКРО'Й** *м.*— 1. к. закроить 1; 2. *порт. сапож.* фасон; 3. *столяр.* уем, уенты.

**ЗАКРО'ЙНЫЙ** — кием кисә торган; *закройные ножницы* — кием кисә торган кайчы.

**ЗАКРО'ЙЩИК** *м.*, **ЗАКРО'ЙЩИЦА** *ж. порт. сапож.* — кием кисүче, аяк киеме кисүче.

**ЗА'КРО'М** *м. обл.*— ашлык бурасы, бура, өсәк.

**ЗАКРУГЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. к. закруглить; 2. борылыш, борылган урын; *закругление пути* — юлның борылган урыны; 3. *перен. (о речи)* шома фраза.

**ЗАКРУГЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. түгәрәклек, йомрылык; 2. *перен. (о стиле)* шомалык.

**ЗАКРУГЛЁННЫЙ** *книж.* — 1. түгәрәкләнгән, йомрыландырылган; 2. *перен.* шома; *закруглённые фразы* — шома фразалар.

**ЗАКРУГЛИ'ТЬ** *сов.*— түгәрәкләү.

**ЗАКРУГЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— түгәрәкләнү.

**ЗАКРУГЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. закруглить.

**ЗАКРУГЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. закруглиться; 2. *страд.* түгәрәкләндерелү.

**ЗАКРУЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(начать кружить)* әйләндерә башлау; әйләнә башлау; 2. *(кружа довести до усталости)* хәлдән тайганчы әйләндерү; 3. башын әйләндерү; *она его совсем закружила* — ул аның бөтенләй башын әйләндерде. ◇ **Закружило в голове** — башым әйләнә башлады.

**ЗАКРУЖИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(начать кружиться)* әйләнә башлау, бөтерелә башлау; 2. *(кружась, дойти до усталости)* хәлдән тайганчы әйләнү; 3. *перен. разг. фам.* баш әйләнү, баш әйләнеп бетү; *закружился я совсем с этим делом* — бу эштән минем башым әйләнеп бетте.

**ЗАКРУТА'СЫ** *ед.* нет, *разг. устар.*— бормалы-сырмалы бизәкләр.

**ЗАКРУТИ'ТЬ** *сов.*— 1. бору, борып кертү, борып кую; *закрутить гайку* — гайканы борып кертү; *закрутить кран* — кранны борып кую; 2. каерып бәйләү; *закрутить руки назад* — кулларны артка каерып бәйләү; 3. бөтереп кую; *закрутить усы* — мыекны бөтереп кую; 4. *разг.* урау, чорнау; *закрутить шарф вокруг шеи* — муенга шарф урау; 5. *перен. разг. фам. (вскружить голову)* баш әйләндерү; 6. *простореч. обл. (запьянствовать)* типтерә башлау, эчә башлау; 7. *простореч.* үткен сүз әйтеп салу, үткен сүз язып ташлау; *закрутить словечко* — үткен сүз әйтеп салу.

**ЗАКРУТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. борылып керү; *винт закрутился* — винт борылып керде; 2. бөтерелү; *верёвка закрутилась* — бау бөтерелгән; 3. *разг. (обвиться)* уралу, чорналу; 4. бөтерелеп күтәрелә башлау; *пыль закрутилась по дороге* — юлдагы тузан бөтерелеп күтәрелә башлады.

**ЗАКРУ'ТКА** *ж.*— 1. *(действие)* бору; борып ныгыту; боргычлау; бөтерү; 2. *(приспособление)* боргыч, боргыч таягы.

**ЗАКРУ'ЧИВАТЬ** *несов.*—к. закрутить 1, 2.

**ЗАКРУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. закрутиться 1, 2; 2. *страд.* борылу, борып кертелү; каерып бәйләнү; бөтерелү; уралу, чорналу.

**ЗАКРУЧИ'НИТЬСЯ** *сов. фольк.*— пошына башлау, кайгыра башлау.

**ЗАКРЫВА'ТЬ** *несов.*— к. закрыть.

**ЗАКРЫВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. закрыться.

**ЗАКРЫ'ТИЕ** *ср.*— ябу; ябылу.

**ЗАКРЫ'ТЫЙ** — 1. ябык; ябылган, бикләнгән; *закрытое окно* — ябык тәрәзә; *дверь, закрытая на замок* — йозак белән бикләнгән ишек; 2. каплаулы, капланган; *закрытый гроб* — капланган табут; 3. йомык, йомылган; *закрытые глаза* — йомык

күзләр, йомылган күзләр; 4. яшерен, ябык; *закрытое голосование* — яшерен тавыш бирү; *закрытое собрание* — ябык җыелыш. ◇ При закрытых дверях — чит кешеләрдән башка. С закрытыми глазами *перен. разг.* — тәвәккәллек итеп, күзне йомып (нәрсә булса шул булыр дип). В закрытом помещении — бина эчендә (тышта түгел).

**ЗАКРЫ'ТЬ** *сов.* — ябу, ябып кую; *закрыть окно* — тәрәзәне ябу; 2. каплау, томалау, томалап алу; *закрыть лицо рукой* — битне кул белән каплау; *туча закрыла небо* — болыт күк йөзен каплады (томалап алды); 3. йому; *закрыть глаза* — күзне йому; 4. бикләү, бикләп кую; *закрыть комнату* — бүлмәне бикләп кую; *закрыть на ключ* — ачкыч белән бикләп кую; 5. туктату; чыгудан туктату; *закрыть журнал* — журналны чыгудан туктату; 6. туктату; ябу; *закрыть заседание* — утырышны ябу; *закрыть воду* — суны ябу. ◇ Закрыть рот *перен.* — авызын томалау (сөйләтмәү, сөйләргә ирек бирмәү). Закрыть глаза *перен. устар.* — үлү.

**ЗАКРЫ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ябылу; *дверь закрылась* — ишек ябылды; 2. каплану, бөркәнү; *закрыться от дождя* — яңгырдан каплану; 3. йомылу; *глаза закрылись* — күзләр йомылдылар; 4. бетәшү; төзәлү; *рана закрылась* — яра бетәште; 5. туктау, чыкмый башлау; *журнал закрылся* — журнал чыкмый башлады.

**ЗАКРЯХТЕ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. ыңгыраша башлау, уфылдый башлау, аһ-ваһ итә башлау; 2. *перен.* зарлана башлау.

**ЗАКУЛИ'СНЫЙ** — 1. *театр.* пәрдә артындагы, сәхнә артындагы; 2. *перен.* яшерен, астыртын; *закулисные переговоры* — яшерен сөйләшүләр.

**ЗА'КУП** *м. истор.* — закуп (борынгы Русьта боярдан бурыч алып, шул бурычны һәм аның процентларын эшләп түләргә тиеш булган крестьян).

**ЗАКУПА'ТЬ** *несов.* — к. закупить.

**ЗАКУПА'ТЬСЯ** I *несов. страд.* — сатып алыну; сатып алып куелу; сатып алып хәзерләнү.

**ЗАКУПА'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — су коену белән мавыгу, озак су коену.

**ЗАКУПИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*купить оптом*) сатып алу, күпләп сатып алу; 2. сатып алып кую, сатып алып хәзерләү; *закупить дрова на зиму* — кышка утын сатып алып кую; 3. *устар.* (*подкупить*) бераз төртү, майлау, взятка белән сатып алу, сыйлык биреп сатып алу.

**ЗАКУ'ПКА** *ж. разг.* — сатып алу, сатып алып кую, сатып алып хәзерләү.

**ЗАКУПНО'Й** *торг.* — сатып алына торган; *закупной материал* — сатып алына торган материал. ◇ Закупной человек *истор.* — кол.

**ЗАКУ'ПОРИВАТЬ** *несов.* — к. закупорить.

**ЗАКУ'ПОРИВАТЬСЯ** *несов.* — к. закупориться.

**ЗАКУ'ПОРИТЬ** *сов.* — 1. бөкеләү, бөке тыгу, бөке тыгып кую; *закупорить бутылку* — шешәнең авызына бөке тыгып кую; 2. *мед.* томалау, юлны каплау; 3. *перен. разг.* (*держать взаперти*) ябып тоту.

**ЗАКУ'ПОРИТЬСЯ** *сов.* — 1. бөкеләнү; *бутылка закупорилась* — шешә бөкеләнгән; 2. *мед.* тыгылу, томалану; *вена закупорилась* — вена (кан тамыры) тыгылган.

**ЗАКУ'ПОРЩИК** *м.*, **ЗАКУ'ПОРЩИЦА** *ж. спец.* — бөкеләүче, бөкеләп торучы.

**ЗАКУ'ПОЧНЫЙ** — сатып алу ...-ы; *закупочный пункт* — сатып алу пункты.

**ЗАКУ'ПЩИК** *м.*, **ЗАКУ'ПЩИЦА** *ж.* — сатып алучы, сатып алып җыючы.

**ЗАКУ'РИВАТЬ** *несов.* — к. закурить 1, 2.

**ЗАКУ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — к. закуриться.

**ЗАКУРИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*зажечь, начать курить*) кабызып җибәрү, тарта башлау; 2. тәмәке төтене белән тутыру; тәмәке төтене белән башны авырттырып бетерү; *вы меня совсем закурили* — тәмәке төтене белән сез минем башны авырттырып бетердегез; 3. *обл.* куа башлау, чыгара башлау; *закурить дёготь* — дегет чыгара башлау; *закурить спирт* — спирт куа башлау.

**ЗАКУРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. яңа башлау; *папироса закурилась* — папирос яна башлады; 2. (*повредить себе курением*) тәмәкене күп тарту аркасында зарарлану; 3. төтен чыга башлау; *закурилась изба* — өйдән төтен чыга башлады.

**ЗАКУСА'ТЬ** *сов. просторен.* — 1. тешләп интектереп бетерү; талау, талап бетерү; *комары меня закусали* — озынборыннар мине тешләп интектереп бетерделәр; *не ходите — собаки закусают* — бармагыз — этләр талар; 2. (*начать кусать*) тешли башлау, талый башлау.

**ЗАКУСИ'ТЬ** I *сов.* — тешләү. ◇ Закусить удила *перен. разг.* — тезгеннән ычкыну, чиктән тыш үз ирекләләнү.

**ЗАКУСИ'ТЬ** II *сов. разг.* — 1. (*поесть немного*) капкалап алу, ашап алу, бераз ашау, йөрәк ялгау; 2. артыннан кабу, артыннан кабып җибәрү; *закусить лекарство конфетой* — дару артыннан конфет кабу.

**ЗАКУ'СКА** *ж.* — 1. *только ед.* (*действие*) ашап алу, капкалап алу; 2. (*еда, кушанье*) закуска, җиңелчә ашамлык. ◇ На закуску *перен. разг. фам. шутл.* — сүз азагында, сүземне йомгаклап.

**ЗАКУ'СЫВАТЬ** I *несов. разг.* — к. закусить I.

**ЗАКУ'СЫВАТЬ** II *несов. разг.* — к. закусить II.

**ЗАКУ'СЫВАТЬСЯ** I *несов. страд. разг.* — тешләнү.

**ЗАКУ'СЫВАТЬСЯ** II *несов. страд. разг.* — артыннан кабып җибәрелү.

**ЗАКУ'Т** *м.*, **ЗАКУ'ТА** *ж. обл.* — абзар (вак терлекләр өчен); 2. келәт, чолан.

**ЗАКУ'ТАТЬ** *сов.* — төрү, чорнау, урау, чолгау.

**ЗАКУ'ТАТЬСЯ** *сов.* — төренү, чорналу, урану, чолгану.

**ЗАКУТИ'ТЬ** *сов. разг.* — эчәргә керешү, эчә башлау, типтерә башлау.

**ЗАКУТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— озак вакыт буена эчеп йөрү, озак вакыт типтерү.

**ЗАКУ'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. закутать.

**ЗАКУ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. закутаться.

**ЗАЛ** *м.*— зал; *зрительный зал* — тамаша залы; *читальный зал* — уку залы.

**ЗА'ЛА** *ж. устар.*— к. зал.

**ЗАЛА'ДИТЬ** *сов. разг. фам.*— 1. такылдау, кат-кат әйтү; *заладить одно и то же* — һаман бернәрсә турында такылдау; 2. гадәтләнү, гадәтләнеп китү; *она заладила ходить в кино* — ул киногa йөрергә гадәтләнеп китте.

**ЗАЛА'ЗИТЬ** *сов. разг.*— үрмәләп менә башлау.

**ЗАЛАКИРОВА'ТЬ** *сов.*— 1. лаклау, лак белән каплау; 2. *перен.* ялтырату.

**ЗАЛАКИРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. залакировать 1.

**ЗАЛА'МЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. заломить.

**ЗАЛА'МЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— бөгеп сындырылу.

**ЗАЛА'ПАТЬ** *сов. простореч. обл.*— тотып пычратып бетерү.

**ЗАЛАСКА'ТЬ** *сов. разг.*— сөеп интектереп бетерү; *заласкать ребёнка* — баланы сөеп интектереп бетерү.

**ЗАЛАТА'ТЬ** *сов. простореч.*—ямау салу.

**ЗАЛА'ЯТЬ** *сов.* — өрә башлау, өрергә тотыну.

**ЗАЛГА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — күп ялганлау, ялган капчыгына әверелү.

**ЗАЛЕГА'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. залегать; 2. *геол.* ятма, ятым; *залегание горных пород* — тау токымнары ятмасы.

**ЗАЛЕГА'ТЬ** несов. — к. залечь.

**ЗАЛЕДЕНЕ'ЛЫЙ** *разг.* — 1. бозланган, бозланып каткан; 2. боз кебек салкын; *руки у него заледенелые* — аның куллары боз кебек салкын.

**ЗАЛЕДЕНЕ'ТЬ** *сов.* — 1. бозлану, боз белән каплану; 2. *перен.* (*закоченеть*) туңу, боз кебек кату.

**ЗАЛЕЖА'ЛЫЙ** *обл.* — 1. озак яткан, яткан, чамадан тыш яткан; 2. озак ятып бозылган; *залежалая рыба* — озак ятып бозылган балык.

**ЗАЛЕЖА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. озак яту, артык яту, чамадан тыш яту; *больной залежался* — авыру озак ята; 2. озак ятып бозылу; *крупа залежалась* — ярма озак ятып бозылган.

**ЗАЛЕЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. залежаться.

**ЗА'ЛЕЖЬ** *ж.* — 1. *геол.* ятма, ятым; *залежи каменного угля* — ташкүмер ятмалары; 2. *с.-х.* калдау җир, яткын җир, кысыр җир (эшкәртелмичә ташланып тора торган җир); 3. *только мн.* озак яткан өемнәр; *залежи товаров* — озак яткан товар өемнәре; 4. *простореч.* озак ятып бозылган товар.

**ЗАЛЕЗА'ТЬ** *несов. разг.* — к. залезть.

**ЗАЛЕ'ЗТЬ** сов. — 1. үрмәләп менү; менү; *залезть на дерево* — агач башына менү; 2. *разг.* керү; *залезть в воду* — суга керү; 3. *простореч.* тыкшыну, кысылу; *залезть в чужую компанию* — чит компаниягә тыкшыну; 4. *разг.* тыгылу; керү; *залезть в чужой карман* — кеше кесәсенә керү; 5. *простореч.* кию; *залезть в халат* — халат кию. ◇ **Залезть в долги** — бурычка бату.

**ЗАЛЕНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ялкаулана башлау, иренә башлау, ялкауланып китү; *он что-то заленился* — ул нәрсәдер ялкаулана башлады, ялкауланып китте.

**ЗАЛЕПЕТА'ТЬ** *сов. разг.* — бытылдый башлау.

**ЗАЛЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. сылау, сылап кую; *залепить трещину* — ярыкны сылап кую; 2. ябыштыру, ябыштырып кую, ябыштырып ямау; *залепить разбитое окно бумагой* — ватык тәрәзәне кәгазь белән ябыштырып кую; 3. *разг.* ябыштырып бетерү; *залепить всю стену газетой* — бөтен стенага газета ябыштырып бетерү. ◇ **Залепить пощёчину** *разг. вульг.* — яңагына салу, чабып җибәрү.

**ЗАЛЕПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. сылану, сылап куелу; ябышу, ябыштырылу; 2. каплану.

**ЗАЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. залепить.

**ЗАЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. залепиться; 2. *страд.* сылап куелу; ябыштырылу; ябыштырып куелу; ябыштырып бетерелү.

**ЗАЛЕТА'ТЬ** I *сов. разг.* — оча башлау.

**ЗАЛЕТА'ТЬ** II *несов.* — к. залететь.

**ЗАЛЕТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. очып барып чыгу, очып менү; *самолёт залетел за полярный круг* — самолёт поляр түгәрәге артына очып барып чыкты; 2. кереп чыгу (сугылу); *лётчикам пришлось залететь за горючим в Севастополь* — летчикларга бензин өчен Севастопольгә кереп чыгарга туры килде; 3. очып керү; *птица залетела в окно* — кош тәрәзәдән очып керде; 4. очып төшү; *искра залетела в паклю* — чаткы сүскә очып төшкән; 5. *перен.* (*унестись воображением*) хыялланып барып чыгу. ◇ **Высоко залететь (по служебной линии)** *перен. разг. фам.* — югары күтәрелү.

**ЗАЛЁТНЫЙ** *разг. нар.-поэт.* — 1. ялгыш очып кергән; *залётная птица* — ялгыш очып кергән кош; 2. көтмәгәндә килгән; *залётный гость* — көтмәгәндә килгән кунак; 3. елдам, җитез; *птицей несётся залётная тройка* — елдам тройка кош кебек оча.

**ЗАЛЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. залечить.

**ЗАЛЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — к. залечиться.

**ЗАЛЕЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. төзәтү; *залечить рану* — яраны төзәтү; 2. *перен. книж.* җиңеләйтү, йомшарту, төзәтү; *залечить душевную скорбь* — кайгыны җиңеләйтү; 3. *разг. фам.* (*лечением измучить*) дәвалап хәлдән тайдыру; күп дәвалап эштән чыгару.

**ЗАЛЕЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. төзәлү; *рана залечилась* — яра төзәлде; 2. *перен.* йомшару, кимү; 3. озак дәваланып зарар китерү, белмичә дәваланып зарар китерү.

**ЗАЛЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. яту, озакка кереп яту; *залечь спать* — йокларга яту; *медведь залёг в берлоге до весны* — аю язга кадәр оясына кереп ятты; 2. яту, яшеренеп яту; *разведчики залегли в кустах* — разведчиклар куаклыкка яшеренеп яттылар; 3. *геол.* яту, урнашу; *руда залегла здесь неглубоко* — руда биредә тирән ятмый (тирән урнашмаган); 4. *перен. книж.* кереп урнашу; *в его душе глубоко залегли впечатления детства* — балачактагы хисләр аның йөрәгенә тирән кереп урнашкан; 5. *безл. разг.* томалану, тыгылу; *в носу залегло* — борын тыгылды.

**ЗАЛИ'В** *м.* — култык, диңгез култыгы.

**ЗАЛИВА'ТЬ** *несов.* — 1. к. залить 1, 2, 3, 4, 5, 6; 2. *просторечн.* эчү, салу; *он здорово заливает* — ул нык эчә; 3. *просторечн.* борчак ату, ялганлау, арттырып сөйләү; *это ты, брат, заливаешь* — монысы инде, туганкай, борчак атасың.

**ЗАЛИВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. залиться.

**ЗАЛИВНО'Й** — 1. су баса торган, су астында кала торган; *заливной луг* — су баса торган болын; 2. сугара торган, сугару ...-ы; *заливная труба* — сугару трубасы; 3. *кулин.* койкалы, өстенә койка сибелгән (ашамлык).

**ЗАЛИ'ВОЧНЫЙ** — коеп ябыштыра торган; *заливочный материал* — коеп ябыштыра торган материал.

**ЗАЛИ'ВЩИК** *м.* — коючы, коеп ябыштыручы.

**ЗАЛИЗА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. ялап тазарту, чистарту; *собака зализала рану* — эт ярасын ялап тазартты; 2. *просторечн.* (*пригладить*) ялап куйган кебек ялтырату, тигезләү (чәчне); 3. (*начать лизать*) ялый башлау, яларга керешү, яларга тотыну.

**ЗАЛИ'ЗЫВАТЬ** *несов. разг.* — зализать.

**ЗАЛИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — 1. ялап тазартылу, чистартылу; 2. ялап куйган кебек ялтыратылу.

**ЗАЛИПА'ТЬ** *несов. разг.* — сылану, ябышу, уралу; *колёса залипают грязью* — тәгәрмәчкә балчык урала (ябыша).

**ЗАЛИ'ПНУТЬ** *сов. разг.* — к. залипать.

**ЗАЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. басу; *вода залила луга* — су болыннарны басты; 2. түгеп пычрату; *залить книгу чернилами* — кара түгеп китапны пычрату; 3. *перен.* тутыру; *солнце залило ярким светом всю комнату* — кояш якты нурлары белән бөтен бүлмәне тутырды; 4. су сибеп сүндерү; *залить огонь* — утны су сибеп сүндерү; 5. кою; *залить фрукты сахаром* — фруктага шикәр ширбәте кою; 6. коеп ямау; *залить самовар свинцом* — самоварны кургаш коеп ямау; 7. ява башлау, коя башлау; *дожди снова залили* — яңгырлар яңадан коя башлады. ◇ **Толпа залила площадь** — мәйдан халык белән тулды.

**ЗАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. су белән каплану, су астында калу; *луга залились водой* — болыннар су астында калган; 2. түгеп пычрану; *ты весь залился супом* — аш түгеп, син бөтенләй пычранып беткәнсең; 3. *разг. кулин.* койкалану; *рыба сегодня хорошо залилась* — балык бүген яхшы койкаланган; 4. яңгыратып ...-п җибәрү; *залиться песней* — яңгыратып җырлап җибәрү; *залиться на гармошке* — яңгыратып гармонь уйнап җибәрү.

**ЗАЛИХВА'ТСКИЙ** *разг.* — бик җилле, бик чая; *парень с залихватским видом* — бик җилле егет.

**ЗАЛО'Г** I *м.* — 1. закладка салу; *залог имущества* — мөлкәтне закладка салу; 2. залог; *денежный залог* — акчалата залог; 3. *перен.* нигез; *чистота — залог здоровья* — чисталык — сәламәтлекнең нигезе.

**ЗАЛО'Г** II *м. грам.* — юнәлеш; *взаимный залог* — уртаклык юнәлеше.

**ЗАЛО'ГОВЫЙ** I — залог...-ы; *залоговая квитанция* — залог квитанциясе.

**ЗАЛО'ГОВЫЙ** II *грам.* — юнәлеш ...-ы; *залоговые различия в глаголе* — фигыльдә юнәлеш аермалары.

**ЗАЛОГОДА'ТЕЛЬ** *м. юр.* — залог бирүче, закладка салучы.

**ЗАЛОГОДЕРЖА'ТЕЛЬ** *м. юр.* — закладка алучы.

**ЗАЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. кую; *заложить тряпку за зеркало* — чүпрәкне көзге артына кую; *заложил куда-то книгу* — китапны каядыр куйган; 2. *разг.* тутыру, тутырып бетерү; *весь стол заложили книгами* — бөтен өстәлне китаплар белән тутырганнар; 3. томалау, каплау, томалап кую, каплап кую; тыгу; *заложить дыру в стене камнями* — стенадагы тишекне ташлар белән томалап кую; *заложить уши ватой* — колакка мамык тыгу; 4. салу, сала башлау; *заложить фундамент* — нигез салу; 5. *перен. книж.* урнаштыру, тудыру; *родители заложили в душу ребёнка любовь к труду* — ата-аналары баланың күңелендә хезмәткә мәхәббәт тудырганнар; 6. җигү; *заложить тройку* — тройка җигү; 7. закладка салу; *заложить часы* — сәгатьне закладка салу; 8. *безл. разг.* тыгылу, томалану; *мне уши заложило* — колакларым томаланды, колакларым тыгылды; 9. билге салып кую; *заложить страницу* — китап бите арасына билге салып кую. ◇ **Грудь заложило** — күкрәгем кыса. **Заложить дверь засовом** — ишекне аркылы агач белән бикләп кую.

**ЗАЛО'ЖНИК** *м.*, **ЗАЛО'ЖНИЦА** *ж.* — заложник (берәр таләпнең үтәлүен тәэмин итү өчен дошман якларның яки үзара сугышучы илләрнең берсе тарафыннан кулга алынган каршы як кешесе).

**ЗАЛО'М** *м. обл.* — залом (эре сельдь балыгы).

**ЗАЛОМИ'ТЬ** *сов.* — 1. бөгеп сындыру; *заломить берёзу* — каенны бөгеп сындыру; 2. *разг. фам.* каеру, куптару (үтә кыйммәт сорау); *сапожник заломил шесть рублей за подмётку* — итекче олтанлык өчен алты сум каерды. ◇ **Заломить шапку** *разг.* — бүрекне кыңгыр салып кую.

**ЗАЛО'СНИВАТЬ** *несов. разг.* — к. залоснить.

**ЗАЛО'СНИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. залосниться 2; 2. *страд.* каешландырып бетерелү.

**ЗАЛОСНИ'ТЬ** *сов. разг.* — каешландыру, каешландырып бетерү; *ты совсем залоснил брюки* — чалбарыңны бөтенләй каешландырып бетергәнсең.

**ЗАЛОСНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (*начать лосниться*) каешлана башлау; 2. каешланып бетү; *локти у пиджака залоснились* — пиджакның терсәкләре каешланып беткән.

**ЗАЛОЩИ'ТЬ** *сов. разг. спец.* — шомарту, ялтырату.

**ЗАЛП** *м.* — залп (берничә мылтыктан яки туптан берьюлы ату).

**ЗА'ЛПОМ** *нареч.* — 1. залп белән; *выстрелить залпом* — залп белән ату; 2. *перен. разг.* берьюлы, бердән; *выпить залпом стакан воды* — бер стакан суны берьюлы эчеп бетерү.

**ЗАЛУПА'ТЬ** *несов. просторец.* — к. залупять.

**ЗАЛУПА'ТЬСЯ** *несов. просторец.* — к. залупляться.

**ЗАЛУПИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (*задрать*) куптару; 2. *просторец. вульг.* (*начать лупить, бить*) дөмбәсли башлау, каты кыйный башлау, тукмый башлау; 3. *просторец.* бик каты кыйнау, үтергәнче кыйнау.

**ЗАЛУПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кубу; *залупилась на пальце кожа* — бармакның тиресе купкан.

**ЗАЛУПЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. залупить 1.

**ЗАЛУПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. залупиться; 2. *страд.* куптарылу.

**ЗАЛУЧА'ТЬ** *несов. разг.* — к. залучить.

**ЗАЛУЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — хәйләләп үз ягына аударылу; чакырып кертелү; алдалап кертелү.

**ЗАЛУЧИ'ТЬ** *сов. разг.* — хәйләләп үз ягына аудару; чакырып алып керү; алдалап кертү.

**ЗАЛЬСТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. ялагайлана башлау, юмакайлана башлау; 2. *просторец. обл.* ялагайланып үз ягына аудару.

**ЗАЛЮБОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — сокланып карап тору.

**ЗАЛЯГА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (*начать лягать*) тибә башлау; 2. тибеп үтерү, типкәләп бетерү.

**ЗАЛЯ'ПАТЬ** *сов. просторец.* — пычратып бетерү; *он заляпал всю тетрадь чернилами* — ул бөтен дәфтәрен кара белән пычратып бетергән.

**ЗАМА'ЗАТЬ** *сов.* — 1. буяу белән каплау, буяп кую; *замазать надпись* — язылган язуны өстеннән буяп кую; 2. сылау, сылап кую; *замазать окна* — тәрәзәләрне сылау; 3. *разг.* буяу, пычрату, пычратып бетерү; *замазать пальто* — пальтоны пычратып бетерү; 4. *перен. разг.* яшерү, каплап калдыру; *замазать недостатки в работе* — эштәге кимчелекләрне яшерү.

**ЗАМА'ЗАТЬСЯ** *сов. разг.* — буялу, пычрану, пычранып бетү.

**ЗАМА'ЗКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. замазать 2; 2. замазка; *замазка для окон* — тәрәзә замазкасы.

**ЗАМА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. замазать 1, 2, 4.

**ЗАМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. буяу белән каплану, буяп куелу; сылану, сылап куелу; 2. *перен.* яшерелү, каплап калдырылу.

**ЗАМА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. замолить.

**ЗАМА'ЛЧИВАТЬ** *несов.* — к. замолчать II.

**ЗАМА'ЛЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — белә торып әйтми калдырылу.

**ЗАМА'НИВАТЬ** *несов.* — к. заманить.

**ЗАМА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кызыктырып кертелү, алдап кертелү, алдап чакырылу; алдап эләктерелү (тотылу).

**ЗАМАНИ'ТЬ** *сов.* — кызыктырып алып керү, алдап кертү, хәйләләп кертү; *заманить неприятельский отряд в болото* — дошман отрядын сазлыкка алдап кертү.

**ЗАМА'НЧИВО** *нареч.* — кызыктырырлык итеп, кызыгырлык итеп.

**ЗАМА'НЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — кызыгырлык булу, кызыктырырлык булу.

**ЗАМА'НЧИВЫЙ** — кызыгырлык, кызыктырырлык, кызыктыра торган, кызыктыргыч.

**ЗАМАРА'ТЬ** *сов.* — 1. (*запачкать*) пычратып бетерү, буяп бетерү; 2. *перен.* хур итү, йөзгә кара ягу.

**ЗАМАРА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. буялып бетү, пычранып бетү; 2. *разг.* үзеңне үзең пычрату, дәрәҗәңне төшерү.

**ЗАМАРА'ШКА** *м.* и *ж. разг. фам.* — шапшак.

**ЗАМА'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. заморить.

**ЗАМА'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.* —1. к. замориться; 2. *страд.* хәлдән тайдырылу, эштән чыгарылу, өшәндерелү, йончытылу.

**ЗАМАРИНОВА'ТЬ** *сов.* — к. мариновать.

**ЗАМАРИНОВА'ТЬСЯ** *сов.* — к. мариноваться.

**ЗАМА'РЫВАТЬ** *несов. просторец.* — к. замарать.

**ЗАМА'РЫВАТЬСЯ** *несов. просторец.* — 1. к. замараться; 2. *страд.* пычратып бетерелү, буяп бетерелү.

**ЗАМА'СЛИВАТЬ** *несов.* — к. замаслить

**ЗАМА'СЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. замаслиться; 2. *страд.* майландырылу, майга буяп бетерелү, майга буяп пычратылу.

**ЗАМА'СЛИТЬ** *сов. разг.* — 1. майландырып бетерү, майга буяп бетерү; *замаслить одежду* — киемне майга буяп бетерү; 2. *перен. фам.* (*лестью, подкупом*) майлау, тәлинкә тоту, юмалау.

**ЗАМА'СЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. майланып бетү, майга буялып бетү; *вся одежда его замаслилась* — аның бөтен киеме майга буялып беткән; 2. *перен.* ялтырый башлау, майлану; *глаза его замаслились* — аның күзләре ялтырый башлады.

**ЗАМАТЕРЕ'ЛЫЙ** *устар.* — чеп-чи, төзәлмәслек; *заматерелый преступник* —

тәзәлмәслек җинаятьче; *заматерелый бюрократ* — чеп-чи бюрократ (ата бюрократ).

**ЗАМАТЕРЕ'ТЬ** *сов. устар.* — катып калу, тәзәлмәслек хәлгә килү.

**ЗАМА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. замотать 1.

**ЗАМА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. замотаться 1, 2; 2. *страд.* чорналу, уралу; 3. *страд.* хәлдән тайдырылу; җәфа чиктерелү.

**ЗАМАХА'ТЬ** *сов.* — 1. болгый башлау; селки башлау; *замахать руками* — кул болгый башлау; 2. кагына башлау, кага башлау; *замахать крыльями* — канат кага башлау.

**ЗАМА'ХИВАТЬСЯ** *несов.* — к. замахнуться.

**ЗАМАХНУ'ТЬСЯ** *сов.* — кизәнү, селтәнү.

**ЗАМА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. замочить.

**ЗАМА'ШКА** *ж. разг. неодобр.* — гадәт, кылану, манера; *барские замашки* — байларча кылану.

**ЗАМА'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. замостить.

**ЗАМА'ЩИВАТЬСЯ** *несов.* — к. замоститься.

**ЗАМА'ЯТЬ** *сов. просторeч.* — интектереп бетерү, алҗытып бетерү, хәлдән тайдырып бетерү; теңкәсенә тиеп бетү, җәфалап бетерү, тинтерәтеп бетерү, борчып бетерү.

**ЗАМА'ЯТЬСЯ** *сов. просторeч.* — интегеп бетү, җәфаланып бетү, хәлдән таю, алҗып бетү, тинтерәп бетү.

**ЗАМАЯ'ЧИТЬ** *сов. обл. спец.* — күренә башлау; *вдали замаячили огни парохода* — ерақта пароход утлары күренә башлады.

**ЗАМЕ'ДЛИТЬ** *сов.* — 1. акрынайту; *замедлить шаги* — адымны акрынайту; 2. кичектерү; *замедлить выполнение решения* — карарны үтәүне кичектерү; 3. кичегү; озакка сузу; *замедлить ответом* — җавапны озакка сузу.

**ЗАМЕ'ДЛИТЬСЯ** *сов.* — 1. акрынаю, акрынлану; *движение поезда замедлилось* — поездның йөреше акрынайды; 2. *устар.* (*задержаться*) кичегү.

**ЗАМЕДЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. замедлить.

**ЗАМЕДЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. замедлиться; 2. *страд.* акрынайтылу; кичектерелү.

**ЗАМЕЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — акшарлау, акбур белән буяу, акбур белән буяп кую; *замелить пятно* — тапны акбур белән буяп кую.

**ЗАМЕЛЬКА'ТЬ** *сов.* — күренә башлау, күренеп-күренеп китә башлау, бер-бер артлы күренә башлау.

**ЗАМЕ'НА** *ж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. заменить; 2. алмаш; *найти себе замену* — үзеңә алмаш табу.

**ЗАМЕНИ'МЫЙ** — алмаштырырлык, алыштырырлык.

**ЗАМЕНИ'ТЬ** *сов.* — 1. алмаштыру, урынына кую; *заменить металл деревом* — металлны агач белән алмаштыру; 2. алмашка килү, алмаштыру; *погибших заменят новые борцы* — һәлак булганнарны яңа көрәшчеләр алмаштырыр.

**ЗАМЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* — алмашыну.

**ЗАМЕНЯ'ТЬ** *несов.* — к. заменить.

**ЗАМЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. замениться; 2. *страд.* алмаштырылу.

**ЗАМЕ'Р** *м.* — үлчәү, үлчәп чыгу (озынлык үлчәве белән).

**ЗАМЕРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. катып калу, тынсыз калу; тыну, тын да чыгармау; *замереть от ужаса* — куркудан катып калу; 2. сүнү, тукталу, туктап калу; *жизнь замерла* — тормыш сүнде; *движение на улице замерло* — урамда хәрәкәт тукталды; 3. тыну; *звуки замерли* — тавышлар тынды.

**ЗАМЕРЗА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. замерзать. ◇ **На точке замерзания** *перен. шутл.* — бер урында, үзгәрешсез.

**ЗАМЕРЗА'ТЬ** *несов.* — к. замёрзнуть.

**ЗАМЁРЗНУТЬ** *сов.* — 1. туңу, кату; *река замёрзла* — елга туңган; 2. өшү; *цветы замёрзли* — чәчәкләр өшегән; 3. *разг.* туңу, өшү; *у меня руки замёрзли* — минем кулларым туңды (өшеде); 4. (*умереть от мороза*) туңып үлү, катып үлү.

**ЗАМЕРТВЕ'ТЬ** *сов. просторeч.* — тоймый башлау; *руки замертвели от холода* — куллар салкыннан тоймый башлады.

**ЗА'МЕРТВО** *нареч.* — үлектәй, үлгән кебек; һушны югалтып; һушсыз хәлдә; *упасть замертво* — һушны югалтып егылу.

**ЗАМЕРЦА'ТЬ** *сов.* — җемелди башлау, җем-җем итә башлау.

**ЗАМЕСИ'ТЬ** *сов.* — 1. басу; *замесить тесто* — камыр басу; 2. туглау, болгату; *замесить суп* — ашка он туглау.

**ЗАМЕСТИ'** *сов.* — 1. себерү, себереп өю; *замести сор в угол* — чүпне почмакка себереп өю; 2. себереп каплау, каплау, күмү, басу; *вьюга замела дорогу* — буран юлны каплаган; 3. *разг.* (*начать мести*) себерә башлау. ◇ **Замести следы** *перен.* — эзне яшерү, эзне югалту; *замести следы преступления* — җинаятьнең эзен яшерү.

**ЗАМЕСТИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ЗАМЕСТИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — 1. урынбасар; *заместитель председателя* — председатель урынбасары; 2. урынына калган кеше, урынына калырлык кеше; *если хотите уйти со службы, найдите себе заместителя* — эшегездән китәргә теләсәгез, урыныгызга калырлык кеше табыгыз.

**ЗАМЕСТИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — урынбасарлык итү (берәүнең урынында вакытлыча эшләп тору).

**ЗАМЕСТИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*заменить*) алыштыру, алмаштыру; 2. (*назначить на вакантное место*) билгеләү, билгеләп кую.

**ЗАМЕ'СТО** *предлог. обл. просторeч.* — к. вместо.

**ЗАМЕТА'ТЬ** I *несов.* — к. замести.

**ЗАМЕТА'ТЬ** II *сов. разг.* — ыргыта башлау, чөя башлау, тондыра башлау, ата башлау. ◇ **Заметать стог** — кибән салу, кибән кую.

**ЗАМЕТА'ТЬ** III *сов. порт.* — типчү, типчеп чыгу, күкләү, күкләп чыгу; *заметать рукава* — җиңнәрне типчеп чыгу.

**ЗАМЕТА'ТЬСЯ** I *несов. страд.* — 1. себерелү, себереп өелү; 2. күмелү, каплану (мәсәлән, юл кар белән).

**ЗАМЕТА'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — әрле-бирле йөри башлау; үрсәләнеп йөри башлау; *от волнения он заметался по комнате* — борчылуыннан ул бүлмә буйлап әрлебирле йөри башлады.

**ЗАМЕ'ТИТЬ** *сов.* — 1. күрү, күреп алу, сизү; *заметить волнение на его лице* — аның йөзендә борчылу сизү; 2. билгеләп кую, искә алып кую, истә калдыру; *заметить улицу* — урамны билгеләп кую; 3. сизү, күрү; *я давно заметил за ним эту привычку* — аның бу гадәтен мин күптәннән сиздем; 4. әйтү, дию; *„это — сказка“, — заметил он* — „бу — әкият“, — диде ул. ◇ **Заметь** *в знач. ввод сл.* — игътибар ит, игътибарга ал.

**ЗАМЕ'ТКА** *ж.* — 1. заметка, кыскача мәкалә; *газетная заметка* — газета заметкасы; 2. язма; *путевые заметки* — юл язмалары; 3. билге, тамга; *делать заметки на деревьях, предназначенных к вырубке* — кисәргә билгеләнгән агачларга билгеләр салып чыгу. ◇ **Брать на заметку** — 1. язып кую; 2. хәтердә (истә) калдыру.

**ЗАМЕ'ТЛИВЫЙ** *простореч.* — дикъкатьле, күзәтүчән, сизгер.

**ЗАМЕ'ТНО** — 1. *нареч.* ачык итеп, билгеле итеп, бераз; сизелерлек дәрәҗәдә; шактый; *он заметно поправился* — ул шактый тазарган; 2. *разг. в знач. ввод. сл.* булса кирәк; *вы, заметно, любитель живописи* — сез сынлы сәнгатьне яратасыз, булса кирәк. ◇ **Чуть заметно** — сизелерсизелмәс кенә; *она чуть заметно улыбнулась* — ул сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды.

**ЗАМЕ'ТНЫЙ** — 1. *(видимый, очевидный)* сизелерлек, сизелеп тора торган, күренеп тора торган, беленеп тора торган; 2. *перен.* күренекле, билгеле, күзгә күренерлек, күзгә чалынырлык; *он стал заметным человеком* — ул күренекле кеше булып китте.

**ЗАМЁТЫВАТЬ** *несов.* — к. заметать III.

**ЗАМЁТЫВАТЬСЯ** *несов. страд. порт.* — типчелү, күкләнү.

**ЗАМЕЧА'НИЕ** *ср.* — 1. *(краткое суждение)* искәрмә, кыскача фикер, күрсәтмә; 2. шелтә, кисәтү, замечание; *сделать замечание школьнику* — мәктәп баласына кисәтү ясау.

**ЗАМЕЧА'ТЕЛЬНО** — 1. *нареч.* искиткеч, бик яхшы, бик шәп, бик әйбәт; *замечательно поёт* — бик яхшы җырлый; 2. *в знач. межд. разг.* бер дә харап, бик шәп, бик яхшы; *замечательно, нечего сказать!* — бер дә харап, әйтәсе дә юк!

**ЗАМЕЧА'ТЕЛЬНЫЙ** — гүзәл; искитәрлек, искиткеч, бик яхшы, бик әйбәт, бик шәп, сокланырлык; *замечательный талант* — искиткеч талант; *замечательный человек* — бик яхшы кеше.

**ЗАМЕЧА'ТЬ** *несов.* — 1. к. заметить 1, 2, 4; 2. сизү, сизә килү; күрү, күрә килү; *я давно замечаю за ним эту привычку* — аның бу гадәтен мин күптәннән сизә киләм.

**ЗАМЕЧА'ТЬСЯ** *сов.* — күренү, күзгә ташлану; сизелү, сизелеп тору.

**ЗАМЕЧТА'ТЬСЯ** *сов.* — хыялга чуму, уйга бату, онытылу.

**ЗАМЕША'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. буталчыклык, чуалчыклык, тәртипсезлек; *внести замешательство в неприятельские ряды* — дошман сафларына тәртипсезлек кертү; 2. *(смущение, растерянность)* каушау, каушап калу, аптырaш.

**ЗАМЕША'ТЬ** I *сов. редко* — болгата башлау, туглый башлау.

**ЗАМЕША'ТЬ** II *сов.* — катнаштыру, тартып кертү, бутау (җинаятькә, начар эшкә); *им не удастся замешать меня в это дело* — алар мине бу эшкә бутый алмаслар.

**ЗАМЕША'ТЬСЯ** *сов.* — 1. катнашу (берәр начар эшкә); *он замешался в неприятную историю* — ул күңелсез эшкә катнашкан; 2. кереп югалу; *замешаться в толпе* — халык арасына кереп югалу.

**ЗАМЕ'ШИВАТЬ** I *несов.* — к. замесить.

**ЗАМЕ'ШИВАТЬ** II *несов.* — замешать II.

**ЗАМЕ'ШИВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — 1. изелү, басылу (камыр турында); 2. туглану, болгатылу (мәсәлән, ашка он).

**ЗАМЕ'ШИВАТЬСЯ** II *несов. разг.* — к. замешаться.

**ЗАМЕ'ШКАТЬ** *сов. обл.* — к. замешкаться.

**ЗАМЕ'ШКАТЬСЯ** *сов. разг.* — озаклау, юанып калу.

**ЗАМЕЩА'ТЬ** *несов.* — 1. к. заместить; 2. урынына калу; *он замещает начальника* — ул начальник урынына калган.

**ЗАМЕЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. алмаштырылу; 2. куелу, билгеләнү.

**ЗАМИГА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. йомгалый башлау; *замигал глазами* — күзләрен йомгалый башлады; 2. җемелди башлау, җемҗем итә башлау; *замигали звёзды* — йолдызлар җемелди башлады.

**ЗАМИНА'ТЬ** *несов. разг.* — к. замять.

**ЗАМИНА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. заматься.

**ЗАМИНИ'РОВАТЬ** *сов.* — к. минировать.

**ЗАМИ'НКА** *ж. разг.* — 1. тоткарлык, комачау; *в деле вышла маленькая заминка* — эштә аз гына тоткарлык килеп чыкты; 2. төртелеп тору; ык-мык итү, тотлыгу; *говорит с заминкой* — тотлыгып сөйли.

**ЗАМИРА'ТЬ** *несов.* — к. замереть.

**ЗА'МКНУТО** *нареч.* — аралашмыйча, бикләнеп, ябылып; *жить замкнуто* — бикләнеп яшәү; аралашмыйча яшәү.

**ЗА'МКНУТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — аралашмау, үзең аерым тоту.

**ЗА'МКНУТЫЙ** — 1. ябык, бикле; *замкнутая дверь* — ябык ишек; 2. аралашмаучы, аралашмый торган, катнашмый торган; тар; *он очень замкнутый человек* — ул бер дә аралашмый торган кеше; *замкну-*

*тая среда* — тар среда; 3. *(скрытный)* астыртын.

**ЗАМКНУ'ТЬ** *сов.* — 1. *просторечь.* бикләү; *замкнуть замок* — йозакны бикләү; 2. тоташтыру; *замкнуть круг* — түгәрәкне тоташтыру.

**ЗАМКНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *просторечь.* бикләнү; *замок замкнулся* — йозак бикләнде; 2. *(соединиться концами)* тоташу; 3. *перен.* аралашмау, бикләнеп яшәү, кеше белән аралашмау; *замкнуться в свою скорлупу* — үз кабыгы эчендә бикләнеп яшәү.

**ЗАМЛЕ'ТЬ** *сов.* — 1. *просторечь.* оюю, өешү (тән); 2. *перен.* эреп китү (берәр тойгыдан).

**ЗАМОГИ'ЛЬНЫЙ** *устар. поэт.* — теге дөньядагы, үлгәннән соңгы.

**ЗАМО'ИНА** *ж. обл.* — ерганак; су баскан урын.

**ЗА'МОК** *м.* — зāмок (1. *истор.* феодал крепосте; 2. сарай; зур алпавыт йорты; 3. революциягә кадәр кайбер сарайларның исеме; кайбер төрмәләрнең исеме). ◇ **Воздушные замки** — тормышка ашырылмаслык хыял.

**ЗАМО'К** *м.* — йозак, бик, бикләвеч. ◇**Держать под замком** — бикләп тоту. **За семью замками** *разг.* — җиде кат җир астында (бик нык яшерелгән).

**ЗАМОЛА'ЖИВАТЬ** *несов. безл. обл.* — томалау, томалап тору, томалый башлау; *замолаживает, видно к дождику* — томалап тора, яңгыр явар, ахрысы.

**ЗАМО'ЛВИТЬ** *сов. разг.*: **замолвить слово (словечко)** — сүз салу, сүз төртеп карау; *замолви перед ним за меня словечко* — аңа минем турымда сүз төртеп кара әле.

**ЗАМОЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — кичертү; *замолить грехи* — гөнаһларны кичертү (дога укып).

**ЗАМОЛКА'ТЬ** *несов.* — 1. к. замолчать 1; 2. к. замолкнуть.

**ЗАМО'ЛКНУТЬ** *сов.* — 1. тыну, тынып калу, туктау, ...-дан туктау; *ребёнок замолк* — бала елаудан туктады; 2. *перен.* сүнү, бетү (хис, фикер һ. б. турында); *любовь замолкла* — мәхәббәт сүнде.

**ЗАМОЛОТИ'ТЬ** *сов. разг.* — (ашлык) суга башлау, сугарга керешү.

**ЗАМОЛО'ТЬ** *сов. просторечь.* — тарта башлау; *мельница замолола* — тегермән тарта башлады.

**ЗАМОЛЧА'ТЬ** I *сов.* — 1. *(прекратить речь* и т. п.) туктау, тукталу, ...-дан туктау; 2. *перен. (затихнуть)* тыну, тынып калу; 3. *(перестать переписываться)* язмый башлау, хатлар язмый башлау; 4. *книж. устар. (перестать действовать)* сүнү.

**ЗАМОЛЧА'ТЬ** II *сов. разг.* — белә торып әйтми калдыру, эндәшми үтү, эчтән тынып калу.

**ЗАМОРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. заморозить.

**ЗАМОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. туңдырылу, катырылу, өшетелү; бик нык суытылу; 2. *перен.* туктатылу, хәрәкәтсез калдырылу.

**ЗАМОРГА'ТЬ** *сов.* — кыса башлау, йомгалый башлау, челт-челт йома башлау; *заморгать глазами* — күзләрне челт-челт йома башлау.

**ЗАМОРИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* һәлак итү, үтерү; *заморить голодом* — ачтан үтерү; 2. *просторечь. (изнурить непосильной работой)* өшәндерү, йончыту, эштән чыгару, азап чиктерү, җәфалау, ябыктыру. ◇ **Заморить червячка** *разг. фам.* — йөрәк ялгау, аз гына капкалап алу, тамак ялгау.

**ЗАМОРИ'ТЬСЯ** *сов. просторечь.* — йончу, хәлдән таю, ару, әлсерәү, эт булу.

**ЗАМОРО'ЗИТЬ** *сов.* — туңдыру, катыру; өшетү; бик нык суыту.

**ЗАМОРО'ЗИТЬСЯ** *сов.* — туңу, өшү, кату, бик нык суыну.

**ЗА'МОРОЗКИ** *ед.* нет — кырау; язгы (көзге) иртәнге суыклар.

**ЗАМОРОСИ'ТЬ** *сов.* — сибәли башлау; *заморосил дождь* — яңгыр сибәли башлады.

**ЗАМО'РСКИЙ** *разг. устар.* — 1. диңгез артындагы, чит илләрдәге; чит илләрдән китерелгән (килгән); *заморские товары* — чит илләрдән китерелгән товарлар; 2. чит ил ...-ы, чит илләр белән ...; *заморская торговля* — чит ил сәүдәсе, чит илләр белән сәүдә.

**ЗАМО'РЫШ** *м. разг.* — бүлтерек, көзге чебеш (үсми калган зәгыйфь тереклек иясе турында әйтелә).

**ЗАМОСТИ'ТЬ** *сов.* — таш җәю, таш түшәү; *замостить улицу* — урамга таш җәю.

**ЗАМОСТИ'ТЬСЯ** *сов.* — таш җәелү, таш түшәлү.

**ЗАМОТА'ТЬ** I *сов. разг.* — 1. *(обмотать)* урау, чорнау; урап кую, сару; 2. *перен. разг.* алҗыту, алҗытып бетерү, иза чиктерү; *дети совсем замотали меня* — балалар мине алҗытып бетерде; 3. *(начать мотать)* чорный (урый) башлау; 4. болгый башлау; чайкый башлау; *замотать головою* — башны чайкый башлау; *замотать хвостом* — койрык болгый башлау.

**ЗАМОТА'ТЬ** II *сов. разг.* — акча туздыра башлау, типтерә башлау, мутлана башлау.

**ЗАМОТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(обмотаться)* чорналу, уралу, сарылу; 2. *перен. (выбиться из сил)* алҗып бетү, хәлдән таю, йөдәп бетү, интегү; 3. *(начать мотаться, качаться)* чайкала башлау, айкала-чайкала башлау.

**ЗАМОЧИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. чылату, юешләү; 2. чылату, суга салу; *замочить коноплю* — киндер чылату (киндер сабагын суга салу).

**ЗАМО'ЧНИК** *м.* — йозакчы, йозак ясаучы.

**ЗАМО'ЧНЫЙ** — йозак ...-ы; *замочная скважина* — йозак тишеге.

**ЗАМУДРИ'ТЬ** *сов. разг.* — акыл сата башлау.

**ЗАМУ'ДРСТВОВАТЬСЯ** *несов. разг.* — акыл сатуга бирелеп китү.

**ЗА'МУЖ** *нареч.*: **1. идти, выйти, пойти, выходить замуж** — кияүгә бару, иргә чыгу; **2. отдать, выдать замуж** — кияүгә бирү; **3.** *устар.* **брать, взять замуж** — өйләнү.

**ЗА'МУЖЕМ** *нареч.* — кияүдә, ирдә.

**ЗАМУ'ЖНИЙ** — ирле, иргә чыккан; ир белән яшәү ...-ы; *замужняя женщина* — ирле хатын; *замужний период жизни* — тормышының ир белән яшәү чоры.

**ЗАМУНДШТУ'ЧИВАТЬ** *несов. спец.* — к. замундштучить.

**ЗАМУНДШТУ'ЧИТЬ** *сов. спец.* — авызлыклау.

**ЗАМУРЛЫ'КАТЬ** *сов. разг.* — мырлый башлау.

**ЗАМУРОВА'ТЬ** *сов.* — замуровать итү (таш стена эченә урнаштырып, өстеннән сылап кую).

**ЗАМУРОВА'ТЬСЯ** *сов. разг. устар.* — бикләнеп яшәү, чыкмыйча яшәү; *он замуровался в своей деревне* — ул үзенең авылыннан чыкмыйча яши.

**ЗАМУРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. замуровать.

**ЗАМУРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. замуроваться; 2. *страд.* замуровать ителү (таш стена эченә урнаштырылып өстән сыланып куелу).

**ЗАМУ'СЛИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — к. замуслить.

**ЗАМУ'СЛИВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — 1. к. замуслиться; 2. *страд.* селәгәйләнделү, селәгәйгә катырылу.

**ЗАМУ'СЛИТЬ** *сов. разг. фам.* — селәгәйләндереп бетерү, селәгәйгә катыру, пычрату, пычратып бетерү; *замуслить края книги* — китап кырыйларын пычратып бетерү.

**ЗАМУ'СЛИТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — селәгәйгә кату, селәгәйләнеп бетү; пычрану, пычранып бетү.

**ЗАМУСО'ЛИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — к. замусолить.

**ЗАМУСО'ЛИВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — 1. к. замусолиться; 2. *страд.* майландырылу, майландырып бетерелү, каешландырып бетерелү.

**ЗАМУСО'ЛИТЬ** *сов. разг. фам.* — майландырып бетерү, майга катырып бетерү, каешландырып бетерү; *замусолить рубашку* — күлмәкне майландырып бетерү.

**ЗАМУСО'ЛИТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — майланып бетү, каешланып бетү, майга катып бетү, майга буялып бетү.

**ЗАМУ'СОРИТЬ** *сов. разг. фам.* — чүпләп бетерү, чүп белән тутыру.

**ЗАМУ'СОРИТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — чүпләнеп бетү, чүп белән тулу.

**ЗАМУТИ'ТЬ** *сов.* — болганчыкландырып бетерү, болгату. ◇ **Он воды не замутит** *разг.* — тыйнак, юаш.

**ЗАМУТИ'ТЬСЯ** *сов.* — болганчыклану, болганчыкланып бетү.

**ЗАМУХРЫ'ШКА** *м. и ж. разг. фам.* — хәчтерүш, өтек (кеше).

**ЗАМУ'ЧИТЬ** *сов.* — 1. *(до смерти)* азаплап үтерү, җәзалап үтерү; 2. *разг. (истомить)* интектерү, интектереп бетерү, җәфалау, җәфалап бетерү, борчу, алҗыту; 3. *(надоесть)* теңкәгә тию, йөдәтеп бетерү, туйдырып бетерү, үзәккә үтү.

**ЗАМУ'ЧИТЬСЯ** *сов.* — интегеп бетү, йөдәп бетү; йончып бетү, алҗып бетү.

**ЗА'МША** *ж. мн.* нет — замша (болан яки пошн тиресеннән эшләнгән йомшак күн).

**ЗА'МШЕВЫЙ** — замша ...; *замшевые перчатки* — замша перчатка.

**ЗАМШЕ'ЛЫЙ** *обл.* — мүкләнгән, мүк белән капланган; *замшелый пень* — мүк белән капланган төп.

**ЗАМШЕ'ТЬ** *сов. обл.* — мүкләнү, мүк белән каплану.

**ЗАМШИ'ТЬ** *сов. обл.* — мүк белән каплау, мүк белән каплап чыгу, мүкләү.

**ЗАМЫВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. замыть.

**ЗАМЫВА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — юылу, юып бетерелү.

**ЗАМЫ'ЗГАТЬ** *сов. простореч.* — туздырып бетерү, пычратып бетерү.

**ЗАМЫ'ЗГАТЬСЯ** *сов. простореч.* — тузып бетү, пычранып бетү.

**ЗАМЫ'КАТЬ** *сов. простореч.* — (йомышка йөртеп) йөдәтеп бетерү, (йомышка йөртеп) интектереп бетерү.

**ЗАМЫКА'ТЬ** *несов.* — 1. к. замкнуть; 2. очлау, очында (иң ахырында) булу, очында (иң ахырында) бару; *замыкать отряд* — отрядның очында (иң ахырында) булу (бару).

**ЗАМЫ'КАТЬСЯ** *сов. простореч.* — алҗып бетү, арып бетү, интегеп бетү.

**ЗАМЫКА'ТЬСЯ** *несов.* — к. замкнуться.

**ЗА'МЫСЕЛ** *м.* — 1. *(то, что задумано)* уй, теләк, максат; 2. *(намерение)* ният, план; 3. мәкер, хәйлә; *коварные замыслы империалистов* — империалистларның мәкерле ниятләре; 4. *только ед. книж.* төп фикер, идея; *замысел автора* — авторның төп фикере.

**ЗАМЫ'СЛИТЬ** *сов. книж. устар.* — к. замышлять.

**ЗАМЫСЛОВА'ТЫЙ** — 1. башваткыч, хикмәтле, әкәмәт, кыен аңлаешлы, четерекле; *замысловатый вопрос* — башваткыч мәсьәлә, четерекле мәсьәлә; *замысловатая игрушка* — әкәмәт уенчык; *замысловатая статья* — кыен аңлаешлы мәкалә; 2. *(о слоге)* кабарынкы; *замысловатая речь* — кабарынкы речь.

**ЗАМЫ'ТЬ** *сов. разг.* — юу, юып бетерү; *замыть пятно* — тапны юып бетерү.

**ЗАМЫЧА'ТЬ** *сов. разг.* — мөгри башлау.

**ЗАМЫШЛЯ'ТЬ** *несов.* — уйлау, уйлап кую, ниятләү, ниятләп кую, хәзерләү.

**ЗАМЫШЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — уйланылу, хәзерләнү.

**ЗАМЯ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. йомып калдыру, туктату, каплап калдыру; *замять дело* — эшне йомып калдыру; 2. бору, борып җибәрү, икенчегә бору, читкә бору; *замять разговор* — сүзне икенчегә бору.

**ЗАМЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(смутиться)* каушап калу, аптырап калу; 2. *(затрудниться в разговоре)* ни әйтергә белми туктапып калу; сүз таба алмый калу.

**ЗАМЯУ'КАТЬ** *сов. разг.*— мияулый башлау.

**ЗАНАВА'ЖИВАТЬ** *несов. с.-х.*— к. занавозить.

**ЗАНАВА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.*— тиресләнү.

**ЗА'НАВЕС** *м.*— 1. пәрдә; 2. *(полог)* чаршау, чыбылдык.

**ЗАНАВЕ'СИТЬ** *сов.*— 1. кору, пәрдә кору; *занавесить окно* — тәрәзәгә пәрдә кору; 2. кору, чыбылдык кору, чаршау кору; *занавесить кровать* — кроватька чыбылдык кору; 3. *простореч.* ябып кую, каплап кую; *занавесить на лето картину* — җәйгә картинаны каплап кую.

**ЗАНАВЕ'СИТЬСЯ** *сов. разг.*— кору, пәрдә кору, каплану; *я занавесился от солнца и заснул* — кояштан капландым да йокыга киттем.

**ЗАНАВЕ'СКА** *ж.*— пәрдә; чаршау; чыбылдык; *задёрнуть занавески на окнах* — тәрәзә пәрдәләрен тартып кую.

**ЗАНАВЕ'ШИВАТЬ** *несов.* — к. занавесить.

**ЗАНАВЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. занавеситься; 2. *страд.* корылу.

**ЗАНАВО'ЗИТЬ** *сов.*— 1. *с.-х. обл.* тиресләү; 2. *простореч. (загрязнить)* тирес белән пычрату, чүпләү.

**ЗАНА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. заносить II.

**ЗАНА'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. заноситься II; 2. *страд.* туздырылу, киеп туздырылу, киеп таушалдырылу, киеп пычратылу.

**ЗАНЕВЕ'СТИТЬСЯ** *сов. простореч.* — буйга җитү, үсеп җитү (кыз бала турында).

**ЗАНЕДУ'ЖИТЬСЯ** *сов. безл. обл.* — хәл китү, кәеф бозылып китү; *мне что-то занедужилось* — минем нәрсәдер кәефем бозылып китте.

**ЗАНЕМЕ'ТЬ** *сов. простореч.*— ою.

**ЗАНЕМОГА'ТЬ** *несов.*— к. занемочь.

**ЗАНЕМО'ЧЬ** *сов.*— авырып китү.

**ЗАНЕ'РВНИЧАТЬ** *сов. разг.* — борчыла башлау, көйсезләнә башлау; дулый башлау.

**ЗАНЕСТИ'** *сов.*— 1. кертеп чыгу; *товарищ занёс мне книгу* — иптәшем миңа китап кертеп чыкты; 2. кертү, теркәү, язып кую; *занести в список* — исемлеккә кертү; *занести в дневник* — көндәлек дәфтәргә язып кую; 3. басу, каплау; *весь берег занесло песком*—бөтен яр буен ком баскан; 4. күтәрү; *занести руку для удара* — сугарга кул күтәрү; 5. күтәреп, күчереп кую; *занести конец бревна* — бүрәнәнең башын күтәреп күчереп кую; 6. тарату; *занести скарлатину* — скарлатина тарату. ◇ **Кто тебя сюда занёс?** — ничек килеп эләктең син биредә? (Кайдан җил ташлады сине биредә?) **Такую чушь (вздор, пустяки) занёс, что уши вянут** — шундый юк-бар нәрсәләр сөйли башлады, түзеп кенә тор.

**ЗАНЕСТИ'СЬ** I *сов. разг.* — 1. *(замечтавшись, увлечься)* хыялга чуму; 2. *(возгордиться)* эреләнеп китү, масаеп китү.

**ЗАНЕСТИ'СЬ** II *сов.*— йомырка сала башлау.

**ЗАНИЖА'ТЬ** *несов.*— к. занизить.

**ЗАНИ'ЗИТЬ** *сов.* — киметү; түбәнәйтү; *занизить нормы выработки* — эшләп чыгару нормаларын киметү.

**ЗАНИМА'ТЕЛЬНО** *нареч. книж.* — кызыклы итеп, күңелле итеп; *занимательно рассказывать* — кызыклы итеп сөйләү.

**ЗАНИМА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— кызыклылык, кызыклы булу.

**ЗАНИМА'ТЕЛЬНЫЙ** — кызыклы, күңелле; *занимательный рассказ* — кызыклы хикәя; *занимательный человек* — күңелле кеше.

**ЗАНИМА'ТЬ** I *несов.*— 1. *(брать взаймы)* бурычка (көтәргә, әҗәткә) алу, бурычка (көтәргә, әҗәткә) алып тору; 2. *(давать взаймы)* бурычка (көтәргә, әҗәткә) бирү, бурычка (көтәргә, әҗәткә) биреп тору.

**ЗАНИМА'ТЬ** II *несов.*— 1. алу, алып тору; *книжные полки занимают всю стену* — китап киштәләре бөтен стенаны алып торалар; 2. к. занять II 2, 3, 4, 5, 6. ◇ **Занимать видное положение** — күренекле урын тоту. **Занимать определённую позицию** — 1) билгеле бер позициягә урнашу (билгеле бер позициядә тору); 2) *перен.* билгеле бер фикердә булу.

**ЗАНИМА'ТЬСЯ** I *несов.*— 1. шөгыльләнү; *заниматься физкультурой* — физкультура белән шөгыльләнү; 2. эшләү; *сегодня у нас в учреждении не занимаются* — бүген безнең учреждениедә эшләмиләр; 3. уку, дәрес хәзерләү; *дети, пора заниматься*— балалар, дәрес хәзерләргә вакыт. ◇ **Заниматься с учениками** — укучылар белән занятие үткәрү. **Заниматься собой** — үзеңнең тышкы кыяфәтеңә артык әһәмият бирү.

**ЗАНИМА'ТЬСЯ** II *несов. страд.* — бурычка алыну.

**ЗАНИМА'ТЬСЯ** III *несов. обл.* — к. заняться II.

**ЗА'НОВО** *нареч.*— яңадан, яңа баштан.

**ЗАНО'ЗА** *ж.* — 1. шырпы; *вытащить занозу из пальца* — бармактан шырпыны тартып алу; 2. *м.* и *ж. перен. простореч. фам. (задира)* бәйләнчек кеше, бәйләнчек.

**ЗАНО'ЗИСТЫЙ** *разг. фам.*— бәйләнчек; *занозистый человек* — бәйләнчек кеше.

**ЗАНОЗИ'ТЬ** *сов.* — шырпы кертү; *занозить палец* — бармакка шырпы кертү.

**ЗАНО'С** *м.*— көрт, кар өеме.

**ЗАНОСИ'ТЬ** I *несов.*— к. занести.

**ЗАНОСИ'ТЬ** II *сов. разг.*— туздыру, пычратып бетерү; *заносить пальто* — пальтоны туздыру.

**ЗАНОСИ'ТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. занестись I; 2. *страд.* кертелү; язып куелу; *имена отличившихся заносятся на доску почё-*

*та* — эштә үзен күрсәткән кешеләрнең исемнәре почёт тактасына язып куела.

**ЗАНОСИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — киелеп тузу, киелеп таушалу.

**ЗАНО'СНЫЙ** *книж.* — читтән кергән; *заносная мода* — читтән кергән мода.

**ЗАНО'СЧИВО** *нареч.* — тәкәбберләнеп, үзен эре тотып; *говорить заносчиво* — үзен эре тотып сөйләү, тәкәбберләнеп сөйләү.

**ЗАНО'СЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәкәбберлек, һавалылык; масаю, кәпрәю.

**ЗАНО'СЧИВЫЙ** — 1. һавалы, тәкәббер, эреләнүчән, масаючан, кәпрәючән; *заносчивый человек* — тәкәббер кеше; 2. масаюлы; *заносчивая речь* — масаюлы речь.

**ЗАНОЧЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — кунып калу.

**ЗАНУМЕРОВА'ТЬ** *сов.* — номерлап чыгу, номерлар сугып чыгу, номерлар куеп чыгу.

**ЗАНУМЕРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. занумеровать.

**ЗАНУМЕРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — номерлар сугылу.

**ЗАНЫ'ТЬ** *сов.* — 1. сызлый башлау, сыкрый башлау, әрни башлау; *у него заныла больная нога* — аның авыру аягы сызлый башлады; 2. *(начать жаловаться)* сукрана башлау.

**ЗАНЯ'НЧИТЬ** *сов.* — 1. карый башлау (баланы); 2. *(замучить неумелым уходом)* (карый белмичә карап) эштән чыгару, интектереп бетерү (баланы).

**ЗАНЯ'ТИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* алу; *занятие крепости* — крепостьны алу; 2. эш; һөнәр; *выбирать себе занятие* — үзенә һөнәр сайлау; *род занятий* — эш төре; 3. *преимущ. мн.* укулар, занятиеләр; *занятия в школе начинаются в восемь часов* — мәктәптә укулар сигездә башлана; *проводить занятия с учениками* — укучылар белән занятиеләр үткәрү; 4. шөгыльләнү; *литературные занятия* — әдәбият белән шөгыльләнү.

**ЗАНЯ'ТНО** *нареч. разг.* — күңелле итеп, кызыклы итеп; *он занятно рассказывает* — ул күңелле итеп сөйли.

**ЗАНЯ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — кызыклылык, күңеллелек, кызыклы булу, күңелле булу.

**ЗАНЯ'ТНЫЙ** *разг. фам.* — күңелле, кызыклы; *занятный человек* — күңелле кеше; *занятный рассказ* — кызыклы хикәя.

**ЗАНЯТО'Й** *разг.* — эше күп; *занятой человек* — эше күп кеше.

**ЗА'НЯТОСТЬ** *ж. мн.* нет — эшлелек, эш белән тәэмин ителгәнлек.

**ЗАНЯ'ТЬ** I *сов.* — 1. *(взять взаймы)* бурычка алу, кетәргә алу, әҗәткә алу; 2. *(дать в займы)* бурычка бирү, кетәргә бирү, әҗәткә бирү.

**ЗАНЯ'ТЬ** II *сов.* — 1. алу; *книги заняли всю полку* — китаплар бөтен киштәне алганнар; *работа заняла весь день* — эш бөтен көнне алды (эш көн буена сузылды); 2. урнашу, алу; *занять квартиру* — квартирага урнашу; *батарея заняла позицию* — батарея позициягә урнашты; *занять место* — урын алу; 3. юандыру, юату; *занять ребёнка играми* — баланы уеннар белән юандыру; 4. кызыксындыру, мавыктыру; *его заняла мысль о поездке в Москву* — аны Москвага бару турындагы фикер кызыксындырды; 5. алу, сугышып алу; *занять неприятельский город* — дошман шәһәрен (сугышып) алу; 6. эш бирү; *занять нового служащего какой-н. работой* — яңа хезмәткәргә берәр эш бирү. ◇ **Занять гостей** — кунакларның күңелен ачу. **Дух заняло** — тын бетте, тын кысылды.

**ЗАНЯ'ТЬСЯ** I *сов.* — 1. шөгыльләнә башлау, керешү, ...-а башлау, ...-рга тотыну, ...-рга керешү; *заняться работой* — эшкә керешү; *заняться спортом* — спорт белән шөгыльләнә башлау; 2. булышу, җитәкчелек итү; *заняться с детьми* — балаларга булышу (берәр эштә); 3. игътибар итү; *этим учеником надо серьёзно заняться* — бу укучыга бик нык игътибар итәргә кирәк.

**ЗАНЯ'ТЬСЯ** II *сов.* — 1. яна башлау, кабынып китү; *костёр занялся* — костёр кабынып китте; 2. ата башлау; *заря занялась* — таң ата башлады. ◇ **Дух занялся** — тын бетте, тын кысылды.

**ЗАО'БЛАЧНЫЙ** — 1. *книж. поэт.* болыт артындагы, болыт аръягындагы; 2. *перен.* буш; *заоблачные мечты* — буш хыяллар.

**ЗАОДНО'** *нареч.* — 1. *(единодушно, сообща)* бергәләп, берьяклы булып, бергәләшеп; 2. *разг.* бер уңайдан, беррәттән; *купите заодно и книгу* — бер уңайдан китап та сатып алыгыз.

**ЗАОЗЁРНЫЙ** — күл артындагы, күлнең аръягындагы.

**ЗАОКЕА'НСКИЙ** *книж.* — океан артындагы, океан аръягындагы.

**ЗАОРА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — акырып җибәрү, акыра башлау.

**ЗАОСТРИ'ТЬ** I *сов. разг. фам.* — тапкыр сүзләр әйтә башлау.

**ЗАОСТРИ'ТЬ** II *сов.* — 1. очлау; очын үткенләү; *заострить карандаш* — карандаш очлау; *заострить копьё* — сөңгенең очын үткенләү; 2. *перен.* кискенләштерү, басым ясау; *заострить вопрос* — мәсьәләне кискенләштерү, мәсьәләгә басым ясау; 3. әһәмият бирү, игътибарны юнәлдерү; *заострить проблему кадров* — кадрлар проблемасына әһәмият бирү; *заострить внимание* — дикъкатьне юнәлдерү.

**ЗАОСТРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. очланып, очлаеп калу; 2. *перен. (о противоречиях и т. п.)* кискенләшү, җитдиләшү.

**ЗАОСТРЯ'ТЬ** *несов.* — к. заострить II.

**ЗАОСТРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. заостриться.

**ЗАО'ХАТЬ** *сов. разг.* — ахылдый башлау, ах-вах итә башлау.

**ЗАО'ЧНИК** *м.* — заочник, читтән торып укучы.

**ЗАО'ЧНО** *нареч.* — 1. читтән торып ...; *обучаться заочно* — читтән торып уку; 2. үзеннән башка; *его избрали заочно* — аны үзеннән башка сайладылар.

**ЗАО'ЧНЫЙ** — 1. үзе югында, үзеннән башка; *заочное решение* — үзе югында хәл итү; *заочный суд* — үзеннән башка ясалган суд; 2. читтән торып ...; *заочное обучение* — читтән торып уку.

**ЗА'ПАД** *м. мн.* нет — 1. көнбатыш; 2. Көнбатыш Европа илләре.

**ЗАПА'ДАТЬ** *сов.* — төшә башлау, коела башлау.

**ЗАПАДА'ТЬ** *несов.* — к. запасть.

**ЗА'ПАДНИК** *м. истор.* — көнбатышчы (Көнбатыш Европа культурасы һәм көнбатышча яшәү формалары яклы кеше).

**ЗА'ПАДНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *истор.* — көнбатышчылык, көнбатыш культурасы алдында баш ию (XIX йөзнең 30—50 елларында барлыкка килгән һәм җәмгыятьнең үсешендә Көнбатыш Европа юлы белән баруны яклый торган агым).

**ЗАПАДНОЕВРОПЕ'ЙСКИЙ** — Көнбатыш Европа ...-ы; *западноевропейские государства* — Көнбатыш Европа дәүләтләре.

**ЗА'ПАДНЫЙ** — көнбатыш ...; *Западная Европа* — Көнбатыш Европа.

**ЗАПАДНЯ'** *ж.* — *(для птиц)* тозак; *(для мышей)* тәбе; *(для зверей)* капкын.

**ЗАПА'ЗДЫВАТЬ** *несов.* — к. запоздать.

**ЗАПАКОВА'ТЬ** *сов.* — төреп бәйләү, төреп бәйләп кую; *запаковать вещи* — әйберләрне төреп бәйләп кую.

**ЗАПАКОВА'ТЬСЯ** *сов.* — төреп бәйләнү, төреп бәйләп куелу.

**ЗАПАКО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. запаковать.

**ЗАПАКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. запаковаться.

**ЗАПА'КОСТИТЬ** *сов. разг. фам.* — пычратып бетерү, шакшыландырып бетерү, әшәкеләндереп бетерү.

**ЗАПА'КОСТИТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — пычранып бетү, әшәкеләнеп бетү, шакшыланып бетү.

**ЗАПА'Л** *м. тех. воен.* — запал, кабызгыч (шартлаучан матдәләрне кабызып җибәрү өчен).

**ЗАПА'ЛЗЫВАТЬ** *несов.* — к. заползать.

**ЗАПА'ЛИВАТЬ** I *несов. простореч.* — к. запалить I.

**ЗАПА'ЛИВАТЬ** II *несов.* — к. запалить II 2.

**ЗАПА'ЛИВАТЬ** III *несов. обл.* — к. запалить III.

**ЗАПА'ЛИВАТЬСЯ** I *несов. простореч.* — яндырылу, кабызылу.

**ЗАПА'ЛИВАТЬСЯ** II *несов. обл.* — 1. к. запалиться; 2. *страд.* *(о лошади)* яндырылу.

**ЗАПАЛИ'ТЬ** I *сов. разг.* — кабызып җибәрү, ут төртү; *запалить солому* — саламга ут төртү; *запалить трубку* — трубканы кабызып җибәрү.

**ЗАПАЛИ'ТЬ** II *сов. разг.* — 1. *(из орудий)* ата башлау, ут ачу; 2. тондыру, бәрү, сугу; *запалить камнем в голову* — башка таш белән тондыру.

**ЗАПАЛИ'ТЬ** III *сов. обл.* — 1. *(опоить)* аягына су төшерү (ат турында); 2. *(загнать)* яндыру (ат турында).

**ЗАПАЛИ'ТЬСЯ** *сов. обл.* — 1. аягына су төшү (ат турында); 2. яну (ат турында).

**ЗАПА'ЛЬЧИВО** *нареч.* — ачуланып, ярсып, кызып.

**ЗАПА'ЛЬЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — кызулык, кызып китү, кызу канлылык, тиз кабынып китү, тиз ачулану; *ответить с запальчивостью* — кызып китеп җавап бирү.

**ЗАПА'ЛЬЧИВЫЙ** — 1. *(о человеке)* кызу, тиз кабынып китүчән, тиз ачуланучан, тиз кызып китүчән, кызу канлы; *запальчивый человек* — кызу кеше; 2. ачулы, ярсулы; *запальчивая речь* — ярсулы речь.

**ЗАПА'МЯТОВАТЬ** *сов. разг. устар.* — оныту, хәтердән чыгару, истән чыгару.

**ЗАПАНИБРА'ТА** *нареч. разг.* — агай-энеләрчә, тартынмыйча, тартынып-нитеп тормыйча.

**ЗАПАНИБРА'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. устар.* — агай-энеләрчә мөгамәлә, ихтирамсыз мөгамәлә.

**ЗАПА'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. запарить 1, 2, 3, 4.

**ЗАПА'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. запариться.

**ЗАПА'РИТЬ** *сов. разг.* — 1. *фам.* *(в бане)* чабындырып хәлдән тайдыру; 2. *тех.* пешекләү, пешекләп йомшарту; *запарить ткань* — тукыманы пешекләп йомшарту; 3. *(обдать кипятком)* пешекләү; 4. *обл.* *(загнать лошадь)* күбеккә төшерү; 5. *безл. разг.* кыздыра башлау; *опять запарило* — көн тагын кыздыра башлады.

**ЗАПА'РИТЬСЯ** *сов.* — 1. *(в бане)* чабынып хәлдән таю, хәлдән тайганчы чабыну, ...-ганчы юыну (мунчада); 2. тиргә бату, шабыр тиргә бату; *лошадь совсем запарилась* — ат шабыр тиргә баткан; 3. *(сильно устать)* арып бетү.

**ЗАПА'РКА** *ж. мн.* нет — 1. *(действие)* парлау, пешекләү; 2. пешекләү казаны.

**ЗАПА'РНИК** *м. с.-х.* — парлагыч, пешекләгеч (терлек азыгын).

**ЗАПАРНО'Й, ЗАПА'РНЫЙ** — 1. пешекли торган, пешекләү ...-ы; *запарной котёл* — пешекләү казаны; 2. пешекләнгән, парда тотылган; *запарные краски* — парда тотылган буяу.

**ЗАПА'РХИВАТЬ** *несов. разг.* — к. запорхнуть.

**ЗАПАРШИ'ВЕТЬ** *сов. простореч.* — таз лану, кырчын басу.

**ЗАПА'РЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. запороть I.

**ЗАПА'РЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — кыйнап үтерелү (камчы, чыбык белән).

**ЗАПА'С** *м.* — запас; *запас товаров* — товарлар запасы; *шить с запасом* — запас калдырып тегү; *костюм с запасом* — запас белән тегелгән костюм (мул итеп тегелгән костюм). ◇ Про запас — кирәк була калса дип, запаска.

**ЗАПАСА'ТЬ** *несов.* — к. запасти.

**ЗАПАСА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. запастись; 2. *страд.* хәзерләп куелу.

**ЗАПА'СЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — хәстәрлелек, хәстәрен күрүчәнлек; *запасливость хозяйки* — хозяйканың хәстәрлелеге.

**ЗАПА'СЛИВЫЙ** — запас хәзерләүчән, запаслы, саклыклы, хәстәрен күрүчән.

**ЗАПАСНО'Й, ЗАПА'СНЫЙ** — 1. запас -...ы; *запасные части машины* — машинаның запас частьлары; 2. *воен.* запастагы; *запасный командный состав* — запастагы командирлар составы; 3. *в знач. сущ.* запаста торучы; *призыв запасных* — запаста торучыларны (армиягә) чакыру.

**ЗАПАСТИ'** *сов.* — хәзерләү, хәзерләп кую.

**ЗАПАСТИ'СЬ** *сов.* — хәзерләп кую; *запастись дровами* — утын хәзерләп кую; *запастись нужными справками* — кирәкле белешмәләр хәзерләп кую. ◇ **Запастись терпением** — чыдарга хәзер булып тору.

**ЗАПА'СТЬ** *сов.* — төшү, төшеп киту. ◇ **Глаза запали** — күзләре эчкә баткан. **Запали бока** — эче эчкә ябышкан, эче утлыккан. **Слова его глубоко запали мне в душу** — аның сүзләре минем күңелемдә нык урнашып калдылар (аның сүзләре миңа нык тәэсир иттеләр).

**ЗАПАТЕНТОВА'ТЬ** *сов. разг.* — патент алу, үз исеменә беркетү.

**ЗА'ПАХ** *м.* — ис; *приятный запах* — хуш ис. ◇ **Слышать запах** — ис тою, ис сизү.

**ЗАПАХА'ТЬ** *сов. с.-х.* — 1. *(вспахать после сева)* сөрү, сөреп күмү; 2. *(начать пахать)* сөрә башлау, сукалый башлау.

**ЗАПА'ХИВАТЬ** I *несов.* — к. запахать 1.

**ЗАПА'ХИВАТЬ** II *несов.* — к. запахнуть.

**ЗАПА'ХИВАТЬСЯ** I *несов. страд. с.-х.* — сөрелү, сөреп күмдерелү.

**ЗАПА'ХИВАТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. запахнуться; 2. *страд.* каплану (кием чабуы турында); 3. *страд.* тартылу, төшерелү (пәрдә турында).

**ЗАПА'ХНУТЬ** *сов.* — ис килә башлау.

**ЗАПАХНУ'ТЬ** *сов.* — 1. чабуны каплау (ябу); *запахнуть шубу* — тун чабуын каплау; 2. тарту, төшерү; *запахнуть занавеску* — пәрдәне тарту.

**ЗАПАХНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — төренү; *запахнуться в халат* — халатка төренү.

**ЗАПА'ЧКАТЬ** *сов. разг.* — 1. пычрату, пычратып бетерү, каралту, буяу; 2. *перен. фам. (опозорить)* кара ягу, пычрату.

**ЗАПА'ЧКАТЬСЯ** *сов.* — пычрану, пычранып бету, буялу.

**ЗАПА'ШКА** *ж. с.-х.* — 1. *(пахота)* сөрү; 2. *(количество запаханного)* сөрелгән җир күләме.

**ЗАПА'ШНИК** *м. с.-х.* — запашник (сай сөрә торган сабан).

**ЗАПАЯ'ТЬ** *сов.* — паять итү, паять итеп ямау; *запаять кастрюлю* — кастрюльне паять итеп ямау.

**ЗАПЕ'В** *м. устар. обл.* — җыр башы (күмәк җырның бер генә кеше җырлый торган өлеше).

**ЗАПЕВА'ЛА** *м.* и *ж.* — 1. башлап җырлаучы (хор белән җырлаганда); 2. *перен.* башлап җибәрүче; *комсомольцы — запевалы социалистического соревнования* — комсомолецлар — социалистик ярышны башлап җибәрүчеләр.

**ЗАПЕВА'ТЬ** *несов.* — башлап җырлау.

**ЗАПЕКА'НКА** *ж.* — запеканка (1. җимеш аракысы; 2. *кулин.* ярмадан яки бәрәнгедән өсте кабыкланганчы кыздырып пешерелгән ашамлык).

**ЗАПЕКА'ТЬ** *несов.* — к. запечь.

**ЗАПЕКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. запечься; 2. *страд.* кызартып пешерелү.

**ЗАПЕЛЕНА'ТЬ** *сов.* — биләү, биләп кую.

**ЗАПЕ'НИТЬ** *сов. книж.* — күбекләндерү, күбекләндереп бетерү.

**ЗАПЕ'НИТЬСЯ** *сов.* — күбекләнә башлау.

**ЗАПЕРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. бикләү, бикләп кую; 2. ябу, туктату; *запереть пролив* — бугазны ябу; *запереть воду* — суны туктату; 3. ябып кую, бикләп кую; *запереть кошку в чулане* — мәчене чоланга ябып кую; 4. камап алу, юлын бикләү; *запереть неприятельский флот* — дошман флотын камап алу.

**ЗАПЕРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. бикләнү; *запереться в комнате* — бүлмәдә бикләнү; 2. *перен. разг. (не признаться)* тану, гаебен танымау.

**ЗАПЕРТО'Й** *разг.* — бикле, бикләнгән, йозаклы.

**ЗАПЕРШИ'ТЬ** *сов. разг.* — кымырҗый башлау, кытыклана башлау; *у меня в горле запершило* — тамак төбем кымырҗый башлады.

**ЗАПЕСТРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. чуарланып күренә башлау; *запестрели поля перед глазами* — күз алдында басулар чуарланып күренә башлады; 2. *перен.* еш очрый башлау, еш күренә башлау (мәсәлән, берәүнең исеме газета-журнал битләрендә); *имя молодого писателя запестрело на страницах журнала* — яшь язучының исеме журнал битләрендә еш очрый башлады.

**ЗАПЕСТРЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — чуарланып күренә башлау.

**ЗАПЕСТРИ'ТЬ** *сов.* — чуарлый башлау. ◇ **У меня запестрило в глазах** — минем күз алларым чуп-чуар булып китте.

**ЗАПЕТУШИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — этәчләнә башлау.

**ЗАПЕ'ТЬ** *сов.* — 1. җырлый башлау, җырлап җибәрү; 2. *(о птицах)* сайрый башлау, сайрап җибәрү; 3. *(о петухе)* кычкыра башлау, кычкырып җибәрү; 4. *разг.* күп җырлап тәмен җибәрү (китәрү); *эту песню совсем запели* — бу җырны күп җырлап бөтенләй тәмен җибәрделәр. ◇ **Запеть другое** — бөтенләй башкача сөйли башлау.

**ЗАПЕЧА'ЛИТЬСЯ** *сов. народ.-поэт.* — пошына башлау, кайгыра башлау.

**ЗАПЕЧА'ТАТЬ** *сов.* — 1. печатьләү, печатьләп кую; *запечатать конверт сургучом* — конвертны сургуч белән печатьләү; *запечатать лабораторию* — лабораторияне печатьләп кую; 2. *(заклеить)* ябыштырып кую.

**ЗАПЕЧА'ТАТЬСЯ** *сов. разг.* — ябышу.

**ЗАПЕЧАТЛЕВА'ТЬ** *несов. книж. устар* к. запечатлеть.

**ЗАПЕЧАТЛЕВА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.*— 1. к. запечатлеться; 2. *страд.* гәүдәләндерелү; күңелдә саклану, күңелдә калдырылу.

**ЗАПЕЧАТЛЕ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. гәүдәләндерү; *запечатлеть в романе тип советского патриота* — романда совет патриоты тибын гәүдәләндерү; 2. (күңелдә) саклау, (күңелдә) калдыру; *запечатлеть в памяти* — күңелдә саклау; 3. *книж. устар.* (*закрепить, засвидетельствовать*) ныгыту, беркетү.

**ЗАПЕЧАТЛЕ'ТЬСЯ** *сов.*— күңелгә сеңеп калу, тирән эз калдыру.

**ЗАПЕЧА'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. запечатать.

**ЗАПЕЧА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. запечататься; 2. *страд.* (*опечатываться*) печатьләнү, печатьләп куелу; 3. (*заклеиваться*) ябыштырылу, ябыштырып куелу.

**ЗАПЕ'ЧНЫЙ** *разг.*— мич артындагы.

**ЗАПЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. камырга төреп пешерү; 2. ...-дан запеканка пешерү.

**ЗАПЕ'ЧЬСЯ** *сов.*— кызарып пешү; *картошка запеклась* — бәрәнге кызарып пешкән. ◇ **Кровь запеклась** — кан оешкан. **Губы запеклись** — иреннәре ярылып беткән.

**ЗАПИВА'ТЬ** *несов.*— к. запить.

**ЗАПИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— артыннан эчелү; *лекарство запивается водой* — дару артыннан су эчелә.

**ЗАПИВО'ХА** *м.* и *ж. простореч. пренебр.*— исерек баш.

**ЗАПИЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. (*начать пилить*) кисә башлау (пычкы белән); 2. *перен. фам.* (*замучить укорами*) туктаусыз тиргәп тору, теңкәгә тию, колак итен ашау, йөдәтеп бетерү.

**ЗАПИНА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— тотлыгу, ык-мык итү.

**ЗАПИ'НКА** *ж. разг.*: **говорить без запинки** — тотлыкмыйча сөйләү.

**ЗАПИРА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — гаепне танымау, инкарь итү.

**ЗАПИРА'ТЬ** *несов.*— к. запереть.

**ЗАПИРА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. запереться; 2. *страд.* бикләнү, бикләп куелу; ябылу, ябып куелу; туктатылу.

**ЗАПИСА'ТЬ** *сов.*— 1. язу, язып кую, язып алу; *записать лекцию* — лекция язу; 2. (*внести в список*) теркәү, теркәп кую, кертү; 3. *устар.* яздыру; *записать дом на жену* — өйне хатын исеменә яздыру.

**ЗАПИСА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. язылу; 2. *разг.* язу белән мавыгып онытылу, яза-яза арып бетү.

**ЗАПИ'СКА** *ж.*— 1. записка, язу; *докладная записка* — доклад язуы; *служебная записка* — хезмәт запискасы; 2. *только мн.* язмалар; *учёные записки* — гыйльми язмалар; *путевые записки* — юл язмалары; 3. *только мн. лит.* (*мемуары, воспоминания*) истәлекләр.

**ЗАПИСНО'Й** — 1. язу ...-ы; *записная книжка* — язу дәфтәре; 2. *разг.* чын, хирес; *записной игрок* — чын уенчы.

**ЗАПИ'СЫВАТЬ** *несов.*— к. записать.

**ЗАПИ'СЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. записаться; 2. *страд.* язып куелу, язылу, язып алыну; теркәлү, теркәп куелу; яздырылу.

**ЗА'ПИСЬ** *ж.*— 1. язу, язып алу, язып кую; *запись народных сказок* — халык әкиятләрен язып алу; 2. язма, язу; *тетрадь с записями* — язулы дәфтәр; 3. *устар.* (*документ*) язу; *метрическая запись* — метрика язуы.

**ЗАПИ'ТЬ** *сов.*— 1. (*запьянствовать*) эчә башлау; баш күтәрмичә эчә башлау; 2. артыннан эчү; *запить лекарство водой* — дару артыннан су эчү.

**ЗАПИХА'ТЬ** *сов. разг.*— тыгызлап тыгу, тыгызлап тыгып кую; *запихать бумаги в портфель* — кәгазьләрне тыгызлап портфельгә тыгып кую.

**ЗАПИ'ХИВАТЬ** *несов.*— к. запихать.

**ЗАПИ'ХИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— тыгызлап тыгылу, тыгызлап тыгып куелу.

**ЗАПИХНУ'ТЬ** *сов. разг.*— тыгызлап тыгып кую.

**ЗАПИ'ЧКАТЬ** *сов. разг. фам.*— тыгындыру, кирәгеннән артык ашату; күп ашатып чирләтү; *запичкать ребёнка конфетами* — баланы конфет ашатып чирләтү.

**ЗАПИЩА'ТЬ** *сов. разг.*— чыелдый башлау; чикылдый башлау; безелди башлау; *запищали комары* — озынборыннар безелди башлады.

**ЗАПЛА'ВАТЬ** *сов. разг.*— йөзә башлау (йөзәргә өйрәнеп җитү).

**ЗАПЛА'ВАТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— йөзә-йөзә арып бетү, күп йөзеп хәлдән таю.

**ЗАПЛА'КАТЬ** *сов.*— елый башлау, елап җибәрү.

**ЗАПЛАНИ'РОВАТЬ** *сов.*— планлаштыру, планлаштырып кую.

**ЗАПЛА'ТА** *ж.*— ямаулык, ямау; *наложить заплату* — ямау салу.

**ЗАПЛАТА'ТЬ** *сов. простореч.*— ямау, ямау салу, ямап кую.

**ЗАПЛАТИ'ТЬ** *сов.*— 1. түләү; 2. *книж.* корбан итү, фида итү; *заплатить жизнью* — җанын корбан итү.

**ЗАПЛЕВА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. төкереп тутыру, төкереп пычратып бетерү; *заплевать пол* — идәнне төкереп тутыру; 2. (*начать плевать*) төкерә башлау; 3. *перен. фам.* яла ягып пычратып бетерү, кара ягу.

**ЗАПЛЁВЫВАТЬ** *несов. разг. фам.*— к. заплевать 1.

**ЗАПЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг. фам.*— төкереп тутырылу, төкереп пычратып бетерелү.

**ЗАПЛЕСКА'ТЬ** *сов.*— 1. чәчрәтеп бетерү, чәчрәтеп чылатып бетерү; 2. (*начать плескать*) чәчрәтә башлау.

**ЗАПЛЕСКА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. чәчри башлау; 2. җилферди башлау; чайкала башлау; *заплескались знамёна* — байраклар җилферди башлады.

**ЗАПЛЁСКИВАТЬ** *несов. разг.*— 1. к. заплескать 2; 2. к. заплеснуть.

**ЗАПЛЕСНЕВЕ'ТЬ** *сов.*— күгәрү.

**ЗАПЛЕСНЕ'ТЬ** *сов. простореч.*— к. заплесневеть.

**ЗАПЛЕСНУ'ТЬ** *сов. разг.* — чәчрәп кереп тулу; *лодку заплеснуло водой* — көймәгә су чәчрәп кереп тулды.

**ЗАПЛЕСТИ'** *сов.* — 1. үрү, үреп кую; *заплести косу* — чәч толымын үрү; 2. бәйли башлау; *заплести кружево* — челтәр бәйли башлау. ◇ **Заплести вздор** — лыкылдый башлау, юк-барны сөйли башлау.

**ЗАПЛЕСТИ'СЬ** *сов. обл.* — к. заплетаться.

**ЗАПЛЕТА'ТЬ** *несов. обл.* — к. заплести.

**ЗАПЛЕТА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. (*с трудом двигаться*) көчкә генә атлау; 2. бәйләнү; *от волнения язык у него заплетается* — дулкынланудан аның теле бәйләнә; 3. *обл.* үрмәләү; *хмель заплетается* — колмак үрмәли; 4. *страд.* үрелү, үреп куелу (мәсәлән, чәч).

**ЗАПЛЕ'ЧНЫЙ** — арка ...-ы; *заплечный мешок* — арка капчыгы. ◇ **Заплечных дел мастер** или **заплечный мастер** *устар.* — палач, баш кисүче.

**ЗАПЛЕ'ШИНА** *ж. обл.* — пеләш (урын).

**ЗАПЛОМБИРОВА'ТЬ** *сов.* — 1. (*запечатать пломбой*) пломба сугу, пломба белән печатьләү (мәсәлән, товар вагонын); 2. пломбалау, пломба кую, пломба куйдыру; *запломбировать зуб* — тешкә пломба кую (куйдыру).

**ЗАПЛОМБИРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. запломбировать.

**ЗАПЛОМБИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. пломбалану, пломба сугылу, пломба белән печатьләнү; 2. пломба куелу, пломбалану, пломба белән ямалу.

**ЗАПЛУТА'ТЬ** *сов. обл.* — адашу; юлдан язу.

**ЗАПЛУТА'ТЬСЯ** *сов. обл.* — к. заплутать.

**ЗАПЛЫ'В** *м. спорт.* — йөзү, йөзеш; *в первом заплыве победила команда „Спартак"* — беренче йөзештә „Спартак" командасы җиңде.

**ЗАПЛЫВА'ТЬ** I *несов.* — к. заплыть I.

**ЗАПЛЫВА'ТЬ** II *несов.* — к. заплыть II.

**ЗАПЛЫ'ТЬ** I *сов.* — 1. йөзеп китү (еракка); 2. йөзеп барып чыгу; *заплыть за остров* — утрау артына йөзеп барып чыгу.

**ЗАПЛЫ'ТЬ** II *сов.* — 1. эреп агу; *свечка заплыла* — шәм эреп акты; 2. каплау, басу; *глаза заплыли жиром* — күзләрен май каплаган (май баскан). ◇ **Глаза заплыли** — күзләре шешенгән.

**ЗАПЛЯСА'ТЬ** *сов. разг.* — бии башлау, биергә керешү, биергә тотыну.

**ЗАПЛЯСА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — бии-бии арып бетү, күп биеп хәлдән таю, артык биеп җибәрү.

**ЗАПНУ'ТЬСЯ** *сов.* — тотлыгу, төртелеп калу.

**ЗАПОВЕ'ДАТЬ** *сов. книж. устар.* — васыять әйтү, васыять итеп калдыру.

**ЗАПОВЕ'ДНИК** *м. офиц.* — заповедник, тыелган урын (сирәк очрый торган үсемлекләрне, җәнлекләрне саклау һәм аларны үрчетү урыны).

**ЗАПОВЕ'ДНЫЙ** — 1. тыелулы; тыелган; *заповедный лес* — (кисү) тыелган урман; 2. *поэт.* бик кадерле, газиз.

**ЗАПОВЕ'ДЫВАТЬ** *несов. книж. устар.* — к. заповедать.

**ЗАПОВЕ'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.* — васыять итеп калдырылу.

**ЗА'ПОВЕДЬ** *ж. книж.* — 1. *рел.* дини закон, дин боерыгы; 2. *перен.* бурыч, васыять; *первая заповедь революции* — революция куйган беренче бурыч.

**ЗАПОГА'НИТЬ** *сов. обл. простореч.* — шакшылатып бетерү, пычратып бетерү.

**ЗАПОДЛИЦО'** *нареч. столяр.* — тигез итеп, бертигез итеп; *сделать порог заподлицо с полом* — бусаганы идән белән тигез итеп ясау.

**ЗАПОДО'ЗРИВАТЬ** *несов.* — к. заподозрить.

**ЗАПОДО'ЗРИТЬ** *сов.* — шикләнү, шикләнә башлау, шиккә төшү, шик тота башлау.

**ЗАПО'ЕМ** *нареч. разг.* — 1. тыелгысыз (рәвештә), бертуктаусыз, баш күтәрмичә; *пить запоем* — тыелгысыз эчү; 2. *перен. разг.* баш күтәрмичә, йотлыгып; *читать запоем* — баш күтәрмичә уку.

**ЗАПОЗДА'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — кичеккәнлек, соңга калганлык, соңга калу.

**ЗАПОЗДА'ЛЫЙ** *разг.* — кичеккән, соңлаган, соңга калган, вакыты үткән.

**ЗАПОЗДА'ТЬ** *сов.* — кичегү, кичегә төшү, соңга калу.

**ЗАПОИ'ТЬ** *сов. разг.* — чамадан тыш күп эчерү.

**ЗАПО'Й** — тыелгысыз эчү, баш күтәрмичә эчү.

**ЗАПО'ЛЗАТЬ** *сов. разг.* — үрмәли башлау, мүкәли башлау, үрмәләп йөри башлау; *ребёнок заползал по полу* — бала идән буйлап үрмәләп йөри башлады.

**ЗАПОЛЗА'ТЬ** *несов.* — к. заползти.

**ЗАПОЛЗТИ'** *сов.* — үрмәләп керү, үрмәләп кереп китү, шуышып керү, шуышып кереп китү.

**ЗАПО'ЛНИТЬ** *сов.* — 1. тутыру; *заполнить ведро картошкой* — чиләкне бәрәңге белән тутыру; *заполнить анкету* — анкета тутыру; 2. тулу, шыгрым тулу; *зрители заполнили зал* — тамашачылар залга тулдылар.

**ЗАПО'ЛНИТЬСЯ** *сов.* — тулу, шыгрым тулу; *площадь заполнилась народом* — мәйдан халык белән тулды.

**ЗАПОЛНЯ'ТЬ** *несов.* — к. заполнить.

**ЗАПОЛНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. заполниться; 2. *страд.* тутырылу.

**ЗАПОЛУЧА'ТЬ** *несов. разг. фам.* — к. заполучить.

**ЗАПОЛУЧИ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — 1. алдан алу, алып кую; 2. алу; *заполучить ценного работника* — бик кирәкле работникны алу.

**ЗАПОЛЫХА'ТЬ** *сов. разг.* — дөрли башлау, дөрләп яна башлау.

**ЗАПОЛЯ'РНЫЙ** — поляр түгәрәге аръягындагы; *заполярный город* — поляр түгәрәге аръягындагы шәһәр.

**ЗАПОЛЯ'РЬЕ** *ср. мн.* нет — Заполярье, поляр түгәрәге аръягы.

**ЗАПОМИНА'ТЬ** *несов.*— к. запомнить 1.

**ЗАПОМИНА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. запомниться; 2. *страд.* истә тотылу, хәтердә тотылу.

**ЗАПО'МНИТЬ** — 1. *сов.* күңелдә калдыру, истә калдыру, хәтердә калдыру; 2. *несов.* (*только с отриц.*) *разг.* хәтерләмәү; *такого урожая старики даже не запомнят* — мондый уңышны картлар да хәтерләмиләр.

**ЗАПО'МНИТЬСЯ** *сов.*— хәтердә калу, истә калу.

**ЗА'ПОНКА** *ж.*— запонка (яканы, җиңне төймәләп куя торган махсус каптырма).

**ЗАПО'Р** I *м.*— 1. *только ед. простореч.* бикләү, ябу; *перед самым запором лавки* — кибет ябу алдыннан гына; 2. бик, келә, бикләгеч; *дверь без запора* — биксез ишек. ◇ **На запоре** — бикле.

**ЗАПО'Р** II *м. мед.*— эч кибү, эч кату, запор.

**ЗАПОРА'ШИВАТЬ** *несов.*— к. запорошить 1.

**ЗАПОРО'ЖЕЦ** *м. истор.*— Запорожье казагы.

**ЗАПОРО'ТЬ** I *сов. разг.*— үтергәнче кыйнау, кыйнап үтерү (камчы белән).

**ЗАПОРО'ТЬ** II *сов.*— бозу; *запороть обрабатываемую деталь* — эшкәртелә торган детальне бозу.

**ЗАПОРОШИ'ТЬ** *сов.*— 1. *безл.* (йомшак кар) каплау; *дорогу запорошило снегом* — юлны йомшак кар каплаган; 2. (йомшак кар) ява башлау, каплый башлау; *запорошил снежок* — йомшак кар ява башлады.

**ЗАПОРХНУ'ТЬ** *сов. разг.*— очып керү, очып барып керү.

**ЗАПОТЕВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. запотеть.

**ЗАПОТЕ'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* парлану, булану; *окно запотело* — тәрәзә парланган; 2. *обл.* тирләү; *лошадь запотела* — ат тирләгән.

**ЗАПО'ТЧЕВАТЬ** *сов. разг. фам. устар.*— артык кыстау, кирәгеннән артык кыстау.

**ЗАПОЧИВА'ТЬ** *сов. устар.*— йокларга яту, йокыга китү.

**ЗАПРА'ВДАШНЫЙ** *обл. простореч.*— чын, хакыйкый.

**ЗАПРАВИ'ЛА** *м. разг.*— эшкуар, башлап йөрүче.

**ЗАПРА'ВИТЬ** *сов.*— 1. тыгу, тыгып кую; *заправить брюки в сапоги* — чалбар балакларын итек кунычына тыгып кую; 2. *кулин.* тәм кертү, тәмләндерү, салу; *заправить суп томатом* — ашка томат салу. ◇ **Заправить лампу** — лампага керосин салу. **Заправить автомобиль** — автомобильгә бензин салу. **Заправить капкан** — капканны кору.

**ЗАПРА'ВИТЬСЯ** *сов.*— 1. *разг.* туйганчы ашау-эчү; 2. (*горючим*) бензин (яки керосин) салу (автомобильгә, тракторга); 3. (*вставиться*) урынына куелу, урынына кертеп куелу.

**ЗАПРА'ВКА** *ж.* — 1. к. заправить; 2. *кулин.* тәм керткеч, тәмләгеч.

**ЗАПРАВЛЯ'ТЬ** *несов. разг.*— 1. к. заправить; 2 *фам.* (эшне) алып бару; *у него в доме всеми делами заправляет бабушка* — аның өендә бөтен эшне әбисе алып бара.

**ЗАПРАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. заправиться; 2. *страд. кулин.* тәм кертелү, тәмләндерелү.

**ЗАПРА'ВСКИЙ** *разг.*— менә дигән; *заправский физкультурник* — менә дигән физкультурник.

**ЗАПРА'ШИВАТЬ** *несов.*— к. запросить.

**ЗАПРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— соратылу, соратып алыну; артык соралу, чамадан тыш соралу.

**ЗАПРЕВА'ТЬ** *несов.*— кыза башлау, черн башлау, бурсый башлау.

**ЗАПРЕ'Т** *м. разг.*— тыю.

**ЗАПРЕТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. офиц.*— тыю ...-ы; *запретительные меры* — тыю чаралары.

**ЗАПРЕТИ'ТЬ** *сов.*— тыю.

**ЗАПРЕ'ТНЫЙ** — тыелган, тыюлы, ябык; *запретная зона* — ябык зона (керү тыелган зона).

**ЗАПРЕЩА'ТЬ** *несов.*— к. запретить.

**ЗАПРЕЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— тыелу

**ЗАПРИМЕ'ТИТЬ** *сов. простореч.*— күреп алу, сизеп алу; истә калдыру, хәтердә калдыру.

**ЗАПРИХО'ДОВАТЬ** *сов.*— приходка кертү, приходка язып кую, керемгә кертү, керемгә язып кую.

**ЗАПРОДАВА'ТЬ** *несов. торг.*— к. запродать.

**ЗАПРОДАВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— алдан сатып куелу.

**ЗАПРОДА'ТЬ** *сов.*— алдан сату, алдан сатып кую.

**ЗАПРОЕКТИ'РОВАТЬ** *сов.*— проектлаштыру, проектка (планга, сметага) кертү.

**ЗАПРОКИ'ДЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. запрокинуть.

**ЗАПРОКИ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. запрокинуться.

**ЗАПРОКИ'НУТЬ** *сов. разг.*— артка ташлау, артка салу; *запрокинуть голову* — башны артка ташлау (салу).

**ЗАПРОКИ'НУТЬСЯ** *сов. разг.*— артка ташлану, артка салыну; *голова запрокинулась* — башы артка ташланган.

**ЗАПРОПАДА'ТЬ** *несов. разг. фам.*— к. запропасть.

**ЗАПРОПАСТИ'ТЬ** *сов. простореч.*— әллә кая кую, югалту, билгесез урынга кую, олактыру.

**ЗАПРОПАСТИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— әллә кая китү, юкка чыгу, юк булу, югалу, олагу; *где ты запропастился?* — син кайда югалдың?

**ЗАПРОПА'СТЬ** *сов. разг. фам.*— китеп югалу, олагу; *опять ты запропадёшь на целый день?* — син тагын көн буена китеп югалырсыңмы?

**ЗАПРО'С** *м.*— 1. запрос, сорау; *сделать запрос правительству* — хөкүмәткә запрос ясау; *послать запрос в учреждение* — уч-

рождениегә сорау җибәрү; 2. (*о цене*) арттырып сорау; 3. *только мн.* ихтыяҗлар, таләпләр; *запросы колхозников* — колхозчыларның ихтыяҗлары.

**ЗАПРОСИ'ТЬ** *сов.* — 1. сорау, сорату, соратып алу, соратып алдыру; *запросить справку с места жительства* — торган урыннан белешмә соратып алдыру; 2. (*о цене*) артык сорау, чамадан тыш сорау.

**ЗАПРОСИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ризалык сорый башлау, рөхсәт сорый башлау.

**ЗА'ПРОСТО** *нареч. разг.* — болай гына, тартынмый-нитми генә, тәкәллефсез генә.

**ЗАПРОТЕСТОВА'ТЬ** *сов.* — протест ясый башлау, протест белдерә башлау.

**ЗАПРОТОКОЛИ'РОВАТЬ** *сов. канц.* — протоколга язу, протоколга язып кую, протоколга кертү.

**ЗАПРОТОКО'ЛИТЬ** *сов. книж.* — к. запротоколировать.

**ЗАПРУ'ДА** *ж.* — буа, вакытлы буа.

**ЗАПРУДИ'ТЬ** *сов.* — 1. буу, буып кую; *речку запрудили* — инешне буып куйдылар; 2. *перен.* тутыру; *толпа запрудила всю улицу* — халык бөтен урамны тутырды (урамны каплап алды).

**ЗАПРУДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. буып куелу; 2. *перен.* шыгрым тулу; *площадь запрудилась людьми* — мәйдан кешеләр белән шыгрым тулды.

**ЗАПРУЖА'ТЬ** *несов.* — к. запрудить.

**ЗАПРУЖА'ТЬСЯ** *несов.* — к. запрудиться.

**ЗАПРУ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. запрудить.

**ЗАПРУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. запружаться.

**ЗАПРЫ'ГАТЬ** *сов.* — 1. сикерә башлау, сикергәли башлау; 2. (*о сердце*) тибә башлау, кага башлау.

**ЗАПРЫ'ГАТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — сикерә-сикерә хәлдән таю, арып бетү.

**ЗАПРЫ'ГИВАТЬ** *несов. разг.* — к. запрыгнуть.

**ЗАПРЫ'ГНУТЬ** *сов. разг.* — 1. сикереп менү; *кошка запрыгнула на стул* — мәче урындыкка сикереп менде; 2. сикереп чыгу; *запрыгнуть за черту* — сызыкның аръягына сикереп чыгу.

**ЗАПРЫ'СКАТЬ** *сов. разг.* — 1. (*начать прыскать*) бөрки башлау, сиптерә башлау; 2. бөркеп чәчрәтеп бетерү.

**ЗАПРЫ'СКИВАТЬ** *несов. разг.* — к. запрыскать 2.

**ЗАПРЯГА'ТЬ** *несов.* — к. запрячь.

**ЗАПРЯГА'ТЬСЯ** *несов.* — җигелү.

**ЗАПРЯ'ЖКА** *ж.* — 1. (*действие*) җигү; 2. җигүле ат; 3. сбруй.

**ЗАПРЯ'ТАТЬ** *сов. разг.* — яшерү, яшереп кую, җыеп кую.

**ЗАПРЯ'ТАТЬСЯ** *сов. разг.* — яшеренү, качу, посу.

**ЗАПРЯ'ТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. запрятать.

**ЗАПРЯ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. запрятаться; 2. *страд.* яшереп куелу.

**ЗАПРЯ'ЧЬ** *сов.* — җигү, җигеп кую.

**ЗАПРЯ'ЧЬСЯ** *сов. разг.* — җигелү.

**ЗАПУ'ГАННОСТЬ** *ж. мн. нет* — курыкканлык.

**ЗАПУ'ГАННЫЙ** — 1. курыккан, куркытылган, өркетелгән, коты алынган; 2. куркак; *запуганный ребёнок* — куркак бала.

**ЗАПУГА'ТЬ** *сов.* — куркыту, куркытып бетерү, котын алу, котын чыгару, өркетү.

**ЗАПУ'ГИВАТЬ** *несов.* — к. запугать.

**ЗАПУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — куркытылу.

**ЗАПУ'ДРИВАТЬ** *несов. разг.* — к. запудрить.

**ЗАПУ'ДРИТЬ** *сов. разг.* — пудра сертү, пудра ягу, пудралау, пудра белән каплау.

**ЗАПУСКА'ТЬ I** *несов.* — к. запустить I.

**ЗАПУСКА'ТЬ II** *несов.* — к. запустить II.

**ЗАПУСКА'ТЬСЯ I** *несов. страд.* — 1. очырылу, очырып җибәрелү; 2. тыгылу; 3. (*о когтях*) батырылу.

**ЗАПУСКА'ТЬСЯ II** *несов. страд.* — 1. (*о хозяйстве*) ташландык хәлгә китерелү, төшенкелек хәленә китерелү; 2. (*о болезни*) аздырылу.

**ЗАПУСТЕ'НИЕ** *ср.* — ташландык хәлдә булу, вәйранлык.

**ЗАПУСТЕ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — ташландык (җимерек) хәлгә килү; *сад запустел* — бакча ташландык хәлгә килгән.

**ЗАПУСТИ'ТЬ I** *сов.* — 1. томыру, ыргыту, җибәрү; *запустить камнем* — таш белән җибәрү (ыргыту); 2. очыру; *запустить змей* — очырткыч очыру; 3. тыгу; *запустить руку в карман* — кулны кесәгә тыгу; 4. батыру; *кошка глубоко запустила когти* — мәче тырнакларын тирән батырды. ◇ **Запустить руки (лапы или когти)**, *перен. разг.* — кул сузу.

**ЗАПУСТИ'ТЬ II** *сов.* — 1. ташландык хәлгә китерү, төшенкелек хәленә китерү, рәтен җибәрү; *запустить хозяйство* — хуҗалыкны ташландык хәлгә китерү; *запустить дела* — эшнең рәтен җибәрү; 2. аздыру; *запустить болезнь* — авыруны аздыру.

**ЗАПУ'ТАННОСТЬ** *ж. мн. нет* — буталчыклык, буталганлык.

**ЗАПУ'ТАННЫЙ** — 1. чуаланган, чәбәләнгән; 2. буталчык; *запутанное дело* — буталчык эш.

**ЗАПУ'ТАТЬ** *сов.* — 1. чуаландыру, чәбәләндерү, чуалту; *запутать верёвку* — бауны чәбәләндерү (чуалту); 2. *перен. разг.* бутау, чуалту; *запутать дело* — эшне чуалту; 3. *перен. разг.* аптырату, аптыратып бетерү, йөдәтеп бетерү, башны әйләндереп бетерү; *запутать вопросами* — сораулар белән аптыратып бетерү; 4. *перен. разг. фам.* бәйләү, тарту, катнаштыру; *запутать в неприятное дело* — күңелсез эшкә тарту.

**ЗАПУ'ТАТЬСЯ** *сов.* — 1. чуалану, чәбәләнү, чуалу; *верёвка запуталась* — бау чуалды (чәбәләнде); 2. эләгү, уралу; *голубь запутался в силке* — күгәрчен тозакка эләкте; *запутаться в полах халата* — халат итәгенә уралу; 3. *разг.* адашу; *запутаться в лесу* — урманда адашу; 4. *перен.*

буталу, буталып бетү; *свидетель запутался* — шаһит буталып бетте; 5. *разг.* бату; *запутаться в долгах* — бурычка бату.

**ЗАПУ'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. запутать.

**ЗАПУ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. запутаться.

**ЗАПУХА'ТЬ** *несов. разг.*— к. запухнуть.

**ЗАПУ'ХНУТЬ** *сов. разг.*— шешенү; *глаза запухли* — күзләре шешенгән.

**ЗАПУШИ'ТЬ** *сов.*— каплау, каплап алу; *иней запушил окно* — тәрәзәне бәс каплаган.

**ЗАПУ'ЩЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. (*о болезни*) аздырылганлык, азган булу; 2. (*о хозяйстве*) ташландыклык, ташландык хәлдә булу.

**ЗАПЫЛА'ТЬ** *сов.*— 1. (*загореться*) дөрләп яна башлау, ялкынланып яна башлау; дөрләп янып китү; 2. *перен.* кызару, кызарып китү; *у него запылали щёки* — аның яңаклары кызарып китте.

**ЗАПЫЛИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. тузанландыру, тузан белән каплау; *запылить ботинки* — ботинкаларны тузанландыру; 2. тузан күтәрү, тузан күтәрә башлау.

**ЗАПЫЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— тузанлану, тузан белән каплану; *одежда запылилась* — кием тузанланган.

**ЗАПЫХА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— сулыш тыгылу, тын бетү, сулыш тараю, гыжлау.

**ЗАПЫХТЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (*о человеке*) мышный башлау; 2. (*о паровозе* и т. п.) ухылдый башлау.

**ЗАПЬЯНЕ'ТЬ** *сов. просторечь.*— исерү, исереп китү.

**ЗАПЬЯ'НСТВОВАТЬ** *сов. разг.*— эчә башлау.

**ЗАПЯ'СТЬЕ** *ср.*— 1. *анат.* беләзек сөяге; 2. *поэт.* (*браслет*) беләзек.

**ЗАПЯТА'Я** *ж.*— 1. (*знак препинания*) өтер; 2. *разг. шутл.* бәла, комачаулык, четереклек; *вот тут-то и запятая!* — менә бөтен бәла дә шунда шул!

**ЗАПЯТНА'ТЬ** *сов.*— 1. тапландыру; тап төшерү; 2. *перен.* пычрату, тап төшерү; *я не запятнаю своё имя* — үземнең исемемне пычратмам; 3. (*в игре*) әбәкләү.

**ЗАРАБА'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. заработать 1.

**ЗАРАБА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. заработаться; 2. *страд.* эшләп табылу.

**ЗАРАБО'ТАТЬ** *сов.*— 1. эшләп табу; *заработать деньги честным трудом* — намуслы хезмәт белән акча эшләп табу; 2. эшли башлау; *машина заработала* — машина эшли башлады.

**ЗАРАБО'ТАТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. күп (озак) эшләп ару, эшли-эшли арып бетү; 2. эш белән мавыгып... сизми калу; 3. *я заработался до полуночи* — эш белән мавыгып ярты төн җиткәнен сизми дә калдым.

**ЗА'РАБОТНЫЙ:** заработная плата — эш хакы, хезмәт хакы.

**ЗА'РАБОТОК** *м.*— эш хакы, хезмәт хакы; *годовой заработок* — еллык эш хакы. ◇ **Уходить на заработки** *устар.*— читкә акча эшләргә китү.

**ЗАРА'ВНИВАТЬ** *несов.*— к. заровнять.

**ЗАРА'ВНИВАТЬСЯ** *несов.*— к. заровняться.

**ЗАРАЖА'ТЬ** *несов.*— к. заразить.

**ЗАРАЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. заразиться; 2. *страд.* (*о болезни*) йоктырылу; (*о воздухе*) агуландырылу.

**ЗАРАЖЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. йогу; йоктыру; 2. агулау, агулану; *заражение крови* — кан агулану; *заражение воздуха* — һаваның агулануы, һаваны агулау.

**ЗАРА'З** *нареч. разг.*— берьюлы.

**ЗАРА'ЗА** *ж. мн.* нет — 1. йогыш; 2. йогышлы авыру, йогышлы чир; 3. *перен.* (*отрицательное влияние*) начар йогынты, агу.

**ЗАРАЗИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. йогучанлык, йогышлылык, 2. *перен.* тәэсир итүчәнлек.

**ЗАРАЗИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. йогышлы, йогучан; *заразительная болезнь* — йогышлы авыру; 2. *перен.* тәэсир итүчән, тәэсир итә торган; *заразительный пример* — тәэсир итә торган үрнәк.

**ЗАРАЗИ'ТЬ** *сов.*— 1. йоктыру; *заразить гриппом* — грипп йоктыру; 2. агулау; *заразить воздух* — һаваны агулау; 3. *перен.* (*увлечь кого-н. чем-н.*) тәэсир итү, мавыктырып үзенә ияртү.

**ЗАРАЗИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. йоктыру, ияртү, эләктерү; *заразиться гриппом* — грипп йоктыру; 2. агулану; *заразиться ядом* — агу белән агулану; 3. *перен.* бирелү; *заразиться общей радостью* — гомуми шатлыкка бирелү (кушылу).

**ЗАРАЗИ'ХА** *ж. бот.*— шомбия (паразит үсемлек).

**ЗАРА'ЗНЫЙ** — йогышлы; *заразная болезнь* — йогышлы авыру. ◇ **Заразный больной** — йогышлы авыру белән авыручы. **Заразное отделение** — йогышлы авырулар бүлеге (больницада).

**ЗАРА'НЕЕ** *нареч.*— алдан, алдан ук; *решить заранее* — алдан ук хәл итү.

**ЗАРАПОРТОВА'ТЬСЯ** *сов. разг. ирон.*— буталып калу, кирәкмәс сүзләр сөйләп ташлау.

**ЗАРАСТА'ТЬ** *несов.*— к. зарасти.

**ЗАРАСТИ'** *сов.*— 1. каплану, үлән белән каплану, басу, үлән басу; *зарасти мхом* — мүк белән каплану; *тропинка заросла* — сукмакны үлән баскан; *зарасти бородой* — сакал басу; 2. *разг.* йомылу, бетәшү; *рана заросла* — яра бетәшкән.

**ЗАРВА'ТЬСЯ** *сов.*— килеп кабу (хәлдән килмәслек эшкә тотынып отылу).

**ЗАРДЕВА'ТЬ** *несов. книж. поэт.*— к. зардеть.

**ЗАРДЕ'ТЬ** *сов. книж. поэт.*— кызарып китү; кызара башлау.

**ЗАРДЕ'ТЬСЯ** *сов.*— к. зардеть.

**ЗАРЕВЕ'ТЬ** *сов.*— 1. үкерә башлау, кычкырып җибәрү; *зверь заревел* — ерткыч хайван үкерә башлады; 2. *разг.* (*заплакать*) кычкырып елап җибәрү.

**ЗА'РЕВО** *ср. мн.* нет — (*отсвет заката*) шәфәкъ; (*отсвет пожара*) шәүлә, кызыллык.

**ЗАРЕВО'Й** *поэт.*— таң ...-ы; шәфәкъ ...-ы; *заревые лучи* — шәфәкъ нурлары, таң нурлары.

**ЗАРЕГИСТРИ'РОВАТЬ** *сов.*— теркәү, теркәп кую, регистрация ясау, регистрацияләү, учётка алу.

**ЗАРЕГИСТРИ'РОВАТЬСЯ** *сов.*— 1. теркәлү, регистрацияләнү; 2. язылышу; *зарегистрироваться в загсе* — загста язылышу; 3. *страд.* теркәп куелу, учётка алыну.

**ЗАРЕ'З** *м. мн.* нет, *простореч.*— бәла, эш харап; *без лодки зарез рыбаку* — балыкчыга көймәсез бәла, көймәсез балыкчының эше харап. ◇ **До зарезу** — бик; *до зарезу нужно* — бик кирәк.

**ЗАРЕ'ЗАТЬ** *сов.*— 1. сую, чалу, бугазлау; *зарезать ягнёнка* — бәрән сую; 2. *обл.* буу, буып үтерү; *волк зарезал телёнка* — бүре бозауны буып үтергән; 3. *перен. разг. фам.* авыр хәлдә калдыру; *если деньги не придут в срок, вы нас зарежете* — әгәр акча вакытында килмәсә, сез безне авыр хәлдә калдырырсыз. ◇ **Без ножа зарезал** *разг.*— үтмәс пычак белән суйды, пычаксыз суйды, үтерде (авыр хәлдә калдырды).

**ЗАРЕ'ЗАТЬСЯ** *сов. разг.*— үз-үзен сую, суелып үлү.

**ЗАРЕЗВИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. (*начать резвиться*) шаяра башлау; 2. шаяру белән мавыгу, шаярып дөньяны оныту.

**ЗАРЕЗЕРВИ'РОВАТЬ** *сов. книж.*—соңыннан әйтү хокукын калдыру.

**ЗАРЕ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. зарезаться; 2. *страд.* суелу, чалыну, бугазлану.

**ЗАРЕКА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— тәүбә итү, ант итү.

**ЗАРЕКОМЕНДОВА'ТЬ** *сов.*: **зарекомендовать себя** — үзен таныту, үзен күрсәтү; *он зарекомендовал себя хорошим работником* — ул үзен яхшы работник итеп танытты.

**ЗАРЕ'ЧНЫЙ** — елга артындагы, елга аръягындагы; *заречная слобода* — елга аръягындагы бистә.

**ЗАРЕ'ЧЬЕ** *ср. мн.* нет — елга аръягы.

**ЗАРЕ'ЧЬСЯ** *сов. разг.*— к. зарекаться.

**ЗАРЖА'ВЕТЬ** *сов.*— тутыгу; күгәрү; *нож заржавел* — пычак тутыккан.

**ЗАРЖА'ТЬ** *сов.*— 1. (*о лошади*) кешнәп җибәрү, кешни башлау; 2. *перен. фам.* (*захохотать*) шаркылдап көлеп җибәрү, кешнәп җибәрү.

**ЗАРИСОВА'ТЬ** *сов.*— рәсемен ясау, рәсемен төшерү.

**ЗАРИСОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— рәсем ясау белән мавыгып оныту.

**ЗАРИСО'ВКА** *ж.*— 1. *только ед.* (*действие*) к. зарисовать; 2. (*рисунок*) рәсем.

**ЗАРИСО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. зарисовать.

**ЗАРИСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. зарисоваться; 2. *страд.* рәсеме ясалу, рәсеме төшерелү.

**ЗА'РИТЬСЯ** *несов.*— кызыгу, күз кызу; *зариться на чужое добро* — кеше байлыгына кызыгу.

**ЗАРНИ'ЦА** *ж.*— арыш камчылау, аҗаган, елдырым.

**ЗАРОБЕ'ТЬ** *сов.*— куркып калу, шүрләп калу.

**ЗАРОВНЯ'ТЬ** *сов.*— тигезләү, күмеп тигезләү; *заровнять яму* — чокырны күмеп тигезләү.

**ЗАРОВНЯ'ТЬСЯ** *сов.*— тигезләнү.

**ЗАРОДИ'ТЬ** *сов.*— тудыру, уяту; *зародить надежду* — өмет тудыру; *зародить сомнение* — шик тудыру.

**ЗАРОДИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— туу, барлыкка килү; *у нас зародилась новая идея* — бездә яңа идея туды.

**ЗАРО'ДЫШ** *м.*— 1. *биол.* яралгы; 2. *бот.* бәбәк, бәбәнәк; 3. *перен.* башлангыч чор; *подавить в зародыше дурную привычку* — начар гадәтне башлангыч чорында ук бетерү.

**ЗАРО'ДЫШЕВЫЙ** — яралгы ...-ы; *зародышевые клетки* — яралгы күзәнәкләре.

**ЗАРОЖДА'ТЬ** *несов. книж.*— к. зародить.

**ЗАРОЖДА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. зародиться; 2. *страд.* тудырылу, уятылу.

**ЗАРОЗОВЕ'ТЬ** *сов.*— алсулана башлау, алсуланып китү; *щёки зарозовели* — яңаклары алсуланып китте.

**ЗАРОИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. күч аера башлау, ил аера башлау; *пчёлы зароились* — умарта кортлары ил аера башлады; 2. туа башлау; *зароились надежды* — өметләр туа башлады.

**ЗАРО'К** *м.*— 1. вәгъдә, сүз, ант (берәр эшне эшләмәскә); 2. *обл.* (*заклятье, заговор*) эфсен, өшкерү.

**ЗАРОКОТА'ТЬ** *сов.*— гөрелди башлау, шаулый башлау; *море зарокотало* — диңгез шаулый башлады.

**ЗАРОНИ'ТЬ** *сов.*— 1. төшерү, төшереп җибәрү; *заронить ключ за сундук* — ачкычны сандык артына төшерү; 2. төшерү; *заронить искру* — очкын төшерү; 3. *перен. книж.* кузгату, тудыру; *заронить любовь* — мәхәббәт тудыру.

**ЗАРОНИ'ТЬСЯ** *сов. устар.*— керү, төшү, кереп урнашу; *в сердце дума заронилась* — күңелгә уй керде.

**ЗАРОНЯ'ТЬ** I *несов.*— к. заронить.

**ЗАРОНЯ'ТЬ** II *сов. простореч.*— төшерә башлау.

**ЗАРОПТА'ТЬ** *сов. книж.*— зарлана башлау, сукрана башлау, зарланырга тотыну (керешү).

**ЗА'РОСЛЬ** *ж.*— куаклык, әрәмәлек; куе үсемлек; *водяные заросли* — судагы куе үсемлекләр.

**ЗАРПЛА'ТА** *ж.*— эш хакы, хезмәт хакы.

**ЗАРУБА'ТЬ** *несов.*— к. зарубить.

**ЗАРУБЕ'ЖНЫЙ** — чит илләр ...-ы, чит илләрдәге; *зарубежная печать* — чит илләр матбугаты.

**ЗАРУБИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*убить*) чабып үтерү; 2. (*сделать зарубку*) киртләү, киртекләү. ◇ **Зарубить себе на лбу** (или **на носу**) *разг. фам.* — колакка киртеп кую, маңгайга язып кую.

**ЗАРУ'БКА** *ж.* — тамга, киртек, уем.

**ЗАРУБЦЕВА'ТЬСЯ** *сов.* — төзәлү, йомылу, бетәшү; *рана зарубцевалась* — яра бетәште.

**ЗАРУБЦО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. зарубцеваться.

**ЗАРУГА'ТЬ** *сов. просторечь.* — сүгеп ташлау, тиргәп ташлау, әрләп ташлау.

**ЗАРУГА'ТЬСЯ** *сов. просторечь.* — 1. сүгенә башлау; 2. *(взаимно)* сүгешә башлау, тиргәшә башлау, әрләшә башлау.

**ЗАРУМЯ'НИВАТЬ** *несов.* — к. зарумянить.

**ЗАРУМЯ'НИВАТЬСЯ** *несов.* — к. зарумяниться.

**ЗАРУМЯ'НИТЬ** *сов.* — кызарту, алсуландыру, алсу төскә кертү; *мороз зарумянил щёки* — салкын яңакларны кызарткан.

**ЗАРУМЯ'НИТЬСЯ** *сов.* — 1. алсулану, алсу төскә керү, кызару; *зарумяниться от мороза* — салкыннан кызару; 2. кызарып пешү; *булки зарумянились* — булкалар кызарып пешкән.

**ЗАРУЧА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. заручиться.

**ЗАРУЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — сүз алып кую, вәгъдә алып кую; *заручиться согласием* — ризалыгын алып кую.

**ЗАРУ'ЧКА** *ж. разг.* — протекция, химая (берәр эштә якларлык кеше, ярдәм итәрлек кеше).

**ЗАРЫВА'ТЬ** *несов.* — к. зарыть.

**ЗАРЫВА'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. зарыться; 2. *страд.* күмеп куелу.

**ЗАРЫВА'ТЬСЯ** II *несов. разг.* — к. зарваться.

**ЗАРЫДА'ТЬ** *сов.* — кычкырып елый башлау; үксеп елый башлау; акырып елый башлау.

**ЗАРЫ'ТЬ** *сов.* — күмү, күмеп кую.

**ЗАРЫ'ТЬСЯ** *сов.* — күмелү; каплану; *зарыться в одеяло* — юрган белән каплану; *зарыться лицом в подушку* — мендәргә йөзтүбән каплану. ◇ **Зарыться в книги** — китапка чуму.

**ЗАРЫЧА'ТЬ** *сов.* — акыра башлау, үкерә башлау.

**ЗАРЯ'** *ж.* (*мн.* зори) — 1. *(утренняя)* таң; *(вечерняя)* шәфәкъ; 2. *перен.* таң; *на заре новой жизни* — яңа тормыш таңында. ◇ **От зари до зари** — кояш батканнан алып, кояш чыкканга кадәр (төне буе). **Ни свет ни заря** *разг.* — бик иртә, таң тишегеннән үк.

**ЗАРЯБИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(воду)* шадраландыра башлау, җыерчыкландыра башлау; 2. чуарланып китү; *у меня зарябило в глазах* — күз алларым чуарланып китте.

**ЗАРЯБИ'ТЬСЯ** *сов.* — җыерчыкланып китү, шадраланып китү (су өсте турында).

**ЗАРЯ'Д** *м.* — 1. заряд; *ружейный заряд* — мылтык заряды; *электрический заряд* — электр заряды; 2. *перен.* көч, запас, дәрман; *заряд энергии* — энергия запасы.

**ЗАРЯДИ'ТЬ** I *сов.* — кору; заряжать итү; *зарядить ружьё* — мылтыкны кору; *зарядить батарею* — батареяны заряжать итү.

**ЗАРЯДИ'ТЬ** II *сов.*: **дождик зарядил на целую неделю** — яңгыр бер атна буена китте; **зарядить одно и то же** — бер балык башын чәйнәү (һаман бер нәрсәне сөйләү); **зарядил ходить в гости** — бар белгәне кунакка йөрү.

**ЗАРЯДИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. корылу, заряжать ителү; 2. *перен.* көч җыю, зарядка алу.

**ЗАРЯ'ДКА** *ж. мн.* нет — 1. к. зарядить I; 2. зарядка; *утренняя зарядка* — иртәнге зарядка.

**ЗАРЯ'ДНЫЙ** — заряд ...-ы; *зарядный ящик* — заряд ящигы.

**ЗАРЯЖА'ТЬ** *несов.* — к. зарядить I.

**ЗАРЯЖА'ТЬСЯ** *несов.* — к. зарядиться.

**ЗАСА'ДА** *ж.* — засада (1. дошман килгәнен саклап торып, аңа көтмәгәндә һөҗүм итү өчен берәр урынга яшеренеп урнашу; 2. засада урыны; 3. засадага куелган отряд, төркем).

**ЗАСАДИ'ТЬ** *сов.* — 1. утырту, утыртып тутыру; *засадить грядку цветами* — түтәлгә чәчәкләр утырту; 2. утырту; *засадить за работу* — эшкә утырту; *засадить в тюрьму* — төрмәгә утырту; *засадить топор в бревно* — балтаны бүрәнәгә утырту (кыстырып калдыру); 3. кундыру; *засадить мяч на крышу* — тупны түбәгә кундыру.

**ЗАСА'ДНИТЬ** *сов. разг.* — кымырҗый башлау, кытыклана башлау; *в горле засаднило* — тамагым кымырҗый башлады.

**ЗАСА'ДНЫЙ** *воен.* — засада ...-ы, засадада торучы; *засадный отряд* — засадада торучы отряд.

**ЗАСА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. засадить.

**ЗАСА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. засесть; 2. *страд.* утыртылу, утыртып тутырылу; *грядки засаживаются различными цветами* — түтәлләргә төрле чәчәкләр утыртыла.

**ЗАСА'ЛИВАТЬ** I *несов. разг.* — к. засалить.

**ЗАСА'ЛИВАТЬ** II *несов.* — к. засолить.

**ЗАСА'ЛИВАТЬСЯ** I *несов. разг.* — 1. к. засалиться; 2. *страд.* майландырылу, май белән тапландырылу.

**ЗАСА'ЛИВАТЬСЯ** II *несов. страд.* — тозлану, тозлап куелу; *огурцы засаливаются в бочках* — кыяр мичкәдә тозлана.

**ЗАСА'ЛИТЬ** *сов. разг.* — майландыру, майга катыру, май белән тапландыру, майландырып бетерү, майга катырып бетерү.

**ЗАСА'ЛИТЬСЯ** *сов.* — майлану, май белән таплану, майланып бетү.

**ЗАСА'РИВАТЬ** *несов.* — к. засорить 1.

**ЗАСА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. засориться; 2. *страд.* чүпләндерелү, чүп-чар белән тутырылу.

**ЗАСА'СЫВАТЬ** *несов.* — к. засосать 2, 3, 4.

**ЗАСА'ХАРИВАТЬ** *несов.* — к. засахарить.

**ЗАСА'ХАРИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. засахариться; 2. *страд.* шикәрләндерелү, шикәр белән катырылу.

**ЗАСА'ХАРИТЬ** *сов.* — шикәрләү, шикәр белән катыру.

**ЗАСА'ХАРИТЬСЯ** — шикәрләнү; *мёд засахарился* — бал шикәрләнгән.

**ЗАСВЕРКА'ТЬ** *сов.* — ялтырый башлау, җем-җем итә башлау, җемелди башлау; *звёзды засверкали* — йолдызлар җемелди башлады; *его глаза засверкали* — күзләре ялтырый башлады. ◇ **Пятки засверкали** — табан ялтыратты, тайды, шылды (бик тиз качып китте).

**ЗАСВЕРЛИ'ТЬ** *сов.* — борау белән тишә башлау, бораулый башлау.

**ЗАСВЕТИ'ТЬ** *сов.* — **1.** яндыру, кабызу; *засветить фонарь* — фонарь яндыру; **2.** *перен. вульг.* ялтырату, тондыру, сугып җибәрү; *засветить оплеуху* — колак төбенә ялтырату, тондыру.

**ЗАСВЕТИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** кабыну, кабынып китү; ялтырап күренә башлау, ялтырый башлау; *засветились огни* — утлар кабынып китте, утлар ялтырап күренә башлады; **2.** *перен.* нурланып китү; яктырып китү, ачылып китү; *выражение его лица засветилось* — аның чырае яктырып китте.

**ЗАСВЕТЛЕ'ТЬ** *сов.* — ялтырап күренә башлау, агарып күренә башлау; *что-то засветлело вдали* — еракта нәрсәдер ялтырап күренә башлады.

**ЗАСВЕТЛЕ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — к. засветлеть.

**ЗА'СВЕТЛО** *нареч. разг.* — яктыда, якты чакта, караңгы төшкәнче; *мы отправились в дорогу засветло* — без юлга яктыда ук чыктык.

**ЗАСВИДЕ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *сов.* — 1. дөресләү; *засвидетельствовать факт* — фактны дөресләү; **2.** раслау; *засвидетельствовать подпись* — имзаны раслау. ◇**Засвидетельствовать почтение** *устар.* — хөрмәт белдерү, ихтирам белдерү.

**ЗАСВИСТА'ТЬ, ЗАСВИСТЕ'ТЬ** *сов. простореч.* — сызгыра башлау; *(о птицах)* сайрый башлау.

**ЗАСЕ'В** *м. с.-х.* — 1. *только ед. (действие)* чәчү; **2.** *(засеянная площадь)* чәчелгән җир; **3.** *(посеянное зерно)* чәчелгән орлык, чәчүлек.

**ЗАСЕВА'ТЬ** *несов.* — к. засеять.

**ЗАСЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — чәчелү.

**ЗАСЕДА'НИЕ** *ср.* — утырыш.

**ЗАСЕДА'ТЕЛЬ** *м. офиц.* — заседатель, утырышчы; *народный заседатель* — халык утырышчысы.

**ЗАСЕДА'ТЬ** *несов.* — утырыш үткәрү, утырыш ясау.

**ЗАСЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. засеять.

**ЗАСЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. засеваться.

**ЗАСЕ'КА** *ж.* — 1. *(в лесу)* кисенте (урманда агачлар киселгән урын); **2.** *истор. воен.* засека (дошманга комачаулау өчен аркылы-торкылы аударылган агачлар).

**ЗАСЕКА'ТЬ** *несов.* — к. засечь.

**ЗАСЕКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. засечься; **2.** *страд.* суктырып үтерелү (камчы, чыбык белән).

**ЗАСЕКРЕ'ТИТЬ** *сов.* — 1. яшерен документлар рәтенә кертү; **2.** яшерен документлар белән эш итәргә рөхсәт итү.

**ЗАСЕКРЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. засекретить.

**ЗАСЕКРЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. *(о документах)* яшерен документлар рәтенә кертелү; **2.** *(о работнике)* яшерен документлар белән эш итәргә рөхсәт ителү.

**ЗАСЕЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — халыкның тыгызлыгы, халык урнашу дәрәҗәсе.

**ЗАСЕЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. халык утырту, урнаштыру; *заселить пустынные места* — буш яткан урыннарга халык утырту; *заселить новый дом рабочими* — яңа йортка эшчеләр урнаштыру; **2.** урнашу, утыру; *рабочие заселили новый дом* — эшчеләр яңа йортка урнаштылар.

**ЗАСЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.*: **этот край заселился ещё в XVII веке** — бу тирәгә XVII йөздә ук халык килеп утырган.

**ЗАСЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. заселить.

**ЗАСЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. заселиться; **2.** *страд.* урнаштырылу; *новые дома заселяются рабочими* — яңа йортларга эшчеләр урнаштырыла.

**ЗАСЕМЕНИ'ТЬ** *сов.* — вак-вак атлап китеп бару.

**ЗАСЕРЕБРИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — көмеш кебек ялтырый башлау; чал керә башлау; *волосы засеребрились* — чәченә чал керә башлаган.

**ЗАСЕРЕ'ТЬ** *сов. разг.* — сорылана башлау; сорыланып күренә башлау.

**ЗАСЕРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — к. засереть.

**ЗАСЕ'СТЬ** *сов.* — 1. (ныклап, озакка) утыру; *засесть за работу* — ныклап эшкә утыру; **2.** утырып калу; *засесть в городе* — шәһәрдә утырып калу; **3.** ябылып утыру; *засесть дома* — өйдә ябылып утыру; **4.** яшеренү; *засесть в траншею* — траншеяга яшеренү; **5.** керә утыру, утырып калу; *пуля засела у него в левом боку* — пуля сул ягында утырып калган. ◇ **Засесть в голову** — башка кереп утыру.

**ЗАСЕ'ЧКА** *ж.* — 1. *(на дереве)* билге, тамга, киртек; **2.** *(на чертеже)* киселеш; **3.** *(действие)* билгеләү, билгеләп кую; *засечка времени* — вакытны билгеләү (билгеләп кую).

**ЗАСЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. *(розгами)* суктырып үтерү; **2.** *(сделать отметку)* билге салу, тамга салу, киртекләү, киртләү; **3.** билгеләү, билгеләп кую; *засечь время* — вакытны билгеләп кую.

**ЗАСЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — аягын бәрү, аягын суктыру (ат турында).

**ЗАСЕ'ЯТЬ** *сов.* — чәчү.

**ЗАСИДЕ'ТЬ** *сов. разг.* — (кунып) пычрату, пычратып бетерү; *мухи засидели всю картину* — чебеннәр бөтен картинаны пычратып бетергәннәр.

**ЗАСИДЕ'ТЬСЯ** *сов.* — озак утыру, утырып калу. ◇ **Засидеться в девках** *простореч.* — сазау, кыз килеш картаю.

**ЗАСИ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. засидеть.

**ЗАСИ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. засидеться; **2.** *страд.* (кунып) пычратылу, пычратып бетерелү.

**ЗАСИ'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет — басымчаклык итү, зарарлы йогынты.

**ЗАСИ'М** *нареч. устар.* — шуннан соң, аннан соң.

**ЗАСИНЕ'ТЬ** *сов.* — зәңгәрләнә башлау; зәңгәрләнеп күренә башлау; *вдали засинело море* — еракта диңгез зәңгәрләнеп күренә башлады.

**ЗАСИНЕ'ТЬСЯ** *сов.* — к. засинеть.

**ЗАСИ'НИВАТЬ** *несов. спец.* — к. засинить.

**ЗАСИНИ'ТЬ** *сов.* — **1.** зәңгәргә буяу; **2.** артык синькалау; *засинить бельё* — керне артык синькалау.

**ЗАСИНЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — к. засинить.

**ЗАСИЯ'ТЬ** *сов.* — **1.** ялтырый башлау; *огни засияли* — утлар ялтырый башлады; **2.** яктырып китү; ачылып китү; *лицо его засияло от радости* — шатлыктан аның йөзе яктырып китте; **3.** балкып күренә башлау, ялтырап күренә башлау, җемелдәп күренә башлау; *засияла звезда* — йолдыз ялтырап күренә башлады; *на небе засиял месяц* — күктә ай балкып күренә башлады. ◇ **Глаза засияли** — күзләре нурланып китте.

**ЗАСКАКА'ТЬ** *сов. разг.* — **1.** сикертеп чаба башлау; сикерә башлау; *лошадь заскакала* — ат сикертеп чаба башлады; *заскакать от радости* — шатлыктан сикерә башлау; **2.** чаптырып барып керү, чаптырып барып чыгу.

**ЗАСКАКА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — чаба-чаба арып бетү.

**ЗАСКА'КИВАТЬ** *несов. разг.* — **1.** к. заскочить; **2.** заскакать 2.

**ЗАСКАНДА'ЛИТЬ** *сов. разг.* — җәнҗал күтәрә башлау, тавыш чыгара башлау.

**ЗАСКВОЗИ'ТЬ** *сов.* — **1.** үтәли күренә башлау; *листья опали, и роща засквозила* — яфраклар коелгач, куаклык үтәли күренә башлады; **2.** күренә башлау; *через густые ветви засквозило голубое небо* — куе ботаклар арасыннан зәңгәр күк күренә башлады; **3.** үтәли җил уйный башлау; *дверь открыли, и засквозило* — ишекне ачкач, үтәли җил уйный башлады.

**ЗАСКИРДОВА'ТЬ** *сов.* — эскерткә салу, эскерткә өеп кую, кибәнгә салу.

**ЗАСКО'К** *м.* — **1.** *(действие)* к. заскочить; **2.** *фам. ирон.* буталу, ялгышу, сәерлек; нормальсезлек; *у него бывают такие заскоки в рассуждениях* — аның фикер йөртүләрендә андый сәерлекләр булгалый.

**ЗАСКОЛЬЗИ'ТЬ** *сов. разг.* — шуа башлау; *заскользить на лыжах* — чаңгыда шуа башлау.

**ЗАСКОРУ'ЗЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** *(огрубелость)* кытыршылык, катылык; **2.** *перен.* тупаслык, дорфалык; **3.** *перен. (косность)* катып калганлык.

**ЗАСКОРУ'ЗЛЫЙ** — **1.** *разг.* кытыршы, каты, бирчәйгән; *заскорузлые руки* — кытыршы (бирчәйгән) куллар; **2.** *перен. книж.* тупас, дорфа; *заскорузлые чувства* — тупас хисләр; **3.** *перен. книж.* катып калган, искереп беткән; *заскорузлые порядки* — катып калган тәртипләр.

**ЗАСКОРУ'ЗНУТЬ** *сов.* — **1.** кытыршылану, кату, бирчәю; *руки заскорузли* — куллар кытырышыланды (бирчәйде); **2.** *перен.* тупаслану, дорфалану; **3.** *перен. (стать косным)* катып калу.

**ЗАСКОЧИ'ТЬ** *сов. простореч.* — **1.** сикереп керү, сикереп барып керү; *заяц заскочил в огород* — куян яшелчә бакчасына сикереп керде; **2.** сикереп менү; *кошка заскочила на крышу* — мәче түбәгә сикереп менде; **3.** *перен. фам.* алга чыгу, тыгылу (башкаларны узарга тырышып).

**ЗАСКРЕЖЕТА'ТЬ** *сов.* — шакырдата башлау; *заскрежетать зубами* — тешләрне шакырдата башлау.

**ЗАСКРЕСТИ'** *сов. разг.* — тырный башлау; *что-то заскребло в сердце* — йөрәкне нәрсәдер тырный башлады.

**ЗАСКРЕСТИ'СЬ** *сов. разг.* — кыштырдый башлау; *заскреблась мышь* — тычкан кыштырдый башлады.

**ЗАСКРИПЕ'ТЬ** *сов.* — шыгырдый башлау; *заскрипела дверь* — ишек шыгырдый башлады.

**ЗАСКУЛИ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — шыңшый башлау, шыңшып елый башлау.

**ЗАСКУЧА'ТЬ** *сов. разг.* — сагына башлау, юксына башлау.

**ЗАСЛА'ТЬ** *сов. разг.* — җибәрү; *заслать в дальние края* — ерак җирләргә җибәрү.

**ЗАСЛЕДИ'ТЬ** *сов. разг.* — пычрак эз калдыру, таптау, таптап пычрату.

**ЗАСЛЕЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — яшь килә башлау.

**ЗАСЛЕПИ'ТЬ** *сов.* — каплау, томалау; *буря заслепила глаза* — давыл күзләрне томалады.

**ЗАСЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. заслепить.

**ЗАСЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов, страд. разг.* — томалану, каплану (күзләр турында).

**ЗАСЛО'Н** *м.* — **1.** *обл. (у печки)* мич капкачы; **2.** *воен.* заслон.

**ЗАСЛОНИ'ТЬ** *сов.* — каплау, каплап алу, ышыклау; *туча заслонила солнце* — болыт кояшны каплады.

**ЗАСЛОНИ'ТЬСЯ** *сов.* — каплану; *солнце заслонилось тучами* — кояш болытлар белән капланды.

**ЗАСЛО'НКА** *ж.* — мич капкачы.

**ЗАСЛОНЯ'ТЬ** *несов.* — к. заслонить.

**ЗАСЛОНЯ'ТЬСЯ** I *несов.* — к. заслониться.

**ЗАСЛОНЯ'ТЬСЯ** II *сов. разг. фам.* — әрле-бирле йөри башлау.

**ЗАСЛУ'ГА** *ж.* — **1.** күрсәткән хезмәт (җәмгыять өчен файдалы булып танылган эш); **2.** *только ед.* кыйммәт, тәкъдир ителерлек як; *заслуга этого произведения состоит в том, что ...* — бу әсәрнең кыйммәте шунда ки... ◇ **По заслугам** — **1.** хезмәтләренә карап; *их наградили по заслугам* — аларны хезмәтләренә карап бүләкләделәр; **2.** урынлы, урынлы рәвештә, тиешенчә; *наказать по заслугам* — урынлы җәза бирү, тиешенчә җәза бирү.

**ЗАСЛУ'ЖЕННО** *нареч.* — урынлы, хаклы рәвештә; тиешенчә.

**ЗАСЛУ'ЖЕННЫЙ. ЗАСЛУЖЁННЫЙ** — 1. казанылган, ирешелгән; *заслуженное доверие* — казанылган ышаныч; 2. урынлы, хаклы; *заслуженная похвала* — урынлы мактау; 3. атказанган; *заслуженный деятель искусства* — атказанган сәнгать эшлеклесе; 4. күп хезмәт күрсәткән; *заслуженный учёный* — күп хезмәт күрсәткән галим.

**ЗАСЛУ'ЖИВАТЬ** *несов.* — 1. к. заслужить 2, 3; 2. хаклы булу, урынлы булу, лаеклы булу; *эта книга заслуживает похвалы* — бу китап макталуга лаеклы.

**ЗАСЛУЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. алу, алуга ирешү, казану; *заслужить награду* — награда алуга ирешү; *заслужить выговор* — шелтә алу; 2. кайтару; *одолжите табачку: я вам потом заслужу* — бераз тәмәке бирегезче, мин сезгә соңыннан кайтарырмын; 3. юу; *заслужить вину подвигом* — батырлык күрсәтеп гаепне юу.

**ЗАСЛУЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — күп хезмәт итү, озак вакыт буена хезмәт итү.

**ЗАСЛУ'ШАТЬ** *сов.* — тыңлау; *заслушать доклад* — доклад тыңлау.

**ЗАСЛУ'ШАТЬСЯ** *сов.* — йотлыгып тыңлау, онытылып тыңлау.

**ЗАСЛУ'ШИВАТЬ** *несов.* — к. заслушать.

**ЗАСЛУ'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. заслушаться; 2. *страд.* тыңлану.

**ЗАСЛЫ'ШАТЬ** *сов.* — 1. (*услышать*) ишетү, ишетеп алу; 2. *разг.* сизү, тою; *заслышать запах* — ис сизү.

**ЗАСЛЫ'ШАТЬСЯ** *сов. разг.* — ишетелү, ишетелә башлау; *заслышался шум мотора* — мотор тавышы ишетелде.

**ЗАСЛЮ'НИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — к. заслюнить.

**ЗАСЛЮНИ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — төкереклэп бетерү, селәгәйләп бетерү.

**ЗАСМА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. засмолить.

**ЗАСМА'ТРИВАТЬ** *несов.* — күз салу, күз төшерү; карап-карап кую; *засматривать в окно* — тәрәзәгә күз салу; *мальчик засматривал в глаза матери* — малай әнисенең күзләренә карап-карап куя иде.

**ЗАСМА'ТРИВАТЬСЯ** *несов.* — к. засмотреться.

**ЗАСМЕ'ИВАТЬ** *несов. разг.*—к. засмеять.

**ЗАСМЕЯ'ТЬ** *сов. разг.* — көлкегә калдыру.

**ЗАСМЕЯ'ТЬСЯ** *сов.* — көлә башлау, көлеп җибәрү.

**ЗАСМОЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. сумалалау; 2. (*запачкать смолой*) сумалага пычрату.

**ЗАСМОРКА'ТЬ** *сов. простореч.* — сеңгереп пычратып бетерү.

**ЗАСМОРКА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — сеңгерә башлау, борын сеңгерә башлау.

**ЗАСМОТРЕ'ТЬСЯ** *сов.*— сокланып карап тору; күзне алмыйча карап тору.

**ЗАСНИМА'ТЬ** *несов.* — к. заснять.

**ЗАСНОВА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. җеп озата башлау, киләп сара башлау; 2. *перен.* әрле-бирле йөри башлау, киләп сара башлау.

**ЗАСНУ'ТЬ** *сов.*—йокыга китү. ◇ **Заснуть вечным сном** *книж. ритор.* — үлү, мәңгелек йокыга китү.

**ЗАСНЯ'ТЬ** *сов.* — төшерү, төшереп алу (рәсем турында).

**ЗАСО'В** *м.* — эшермә, бик, аркылы бик (ишектә, капкада).

**ЗАСО'ВЕСТИТЬСЯ** *сов. простореч.* — оялып китү.

**ЗАСО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. засунуть.

**ЗАСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— тыгып куелу, тыгылу.

**ЗАСО'Л** *м. мн.* нет — 1. (*действие*) к. засолить; 2. тозлану дәрәҗәсе; *огурцы слабого засола* — җиңелчә тозланган кыяр.

**ЗАСОЛИ'ТЬ** *сов.* — тозлау, тозлап кую.

**ЗАСО'ЛОЧНЫЙ** — тозлау ...-ы; *засолочный цех* — тозлау цехы.

**ЗАСО'ЛЬЩИК** *м.*, **ЗАСО'ЛЬЩИЦА** *ж.* — тозлаучы, тозлау остасы.

**ЗАСОПЕ'ТЬ** *сов. разг.* — мышный башлау.

**ЗАСОРЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — чүплелек, чүп белән капланганлык.

**ЗАСОРИ'ТЬ** *сов.* — 1. чүпләү, чүпләндерү; *засорить пол* — идәнне чүпләү; 2. чүп кертү; *засорить глаза* — күзгә чүп керү; 3. чүп-чар белән тыгылдыру; *засорить трубу* — трубаны чүп-чар белән тыгылдыру; 4. *перен.* чүп-чар тутыру; *засорить голову* — башка чүп-чар тутыру; 5. *разг.* чүпли башлау. ◇ **Засорить желудок** — ашказанын бозу.

**ЗАСОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. чүпләнү; 2. (*о глазах*) чүп керү; 3. тыгылу; *труба засорилась* — труба тыгылган. ◇ **Засорился желудок** — ашказаны бозылды.

**ЗАСОРЯ'ТЬ** *несов.* — к. засорить.

**ЗАСОРЯТ'ЬСЯ** *несов.* — 1. к. засориться; 2. *страд.* чүпләндерелү.

**ЗАСО'С** *м. мн.* нет — суыру, суырып йоту, үзенә суыру.

**ЗАСОСА'ТЬ** *сов.* — 1. (*начать сосать*) имә башлау, суыра башлау, имәргә керешү, суырырга керешү; 2. *разг.* имә-имә эштән чыгару; *котята совсем засосали кошку*— балалары имә-имә мәчене бөтенләй эштән чыгарганнар; 3. йоту, йотып җибәрү; *ребёнок чуть не засосал соску* — бала имезлеген чак кына йотып җибәрмәгән; 4. *перен.* йоту; кереп бату (берәр начар средага).

**ЗАСО'ХНУТЬ** *сов.* — 1. кору; *цветы засохли* — чәчәкләр корыганнар; 2. кату; катып бетү; *булка засохла* — булка каткан; 3. кибү; кибеп бетү; *краска засохла*— буяу кипкән (кибеп беткән).

**ЗАСОЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — тама башлау, саркып чыга башлау.

**ЗАСПА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. йоклаганда (янында яткан баланы) ялгыш тончыктырып үтерү; *мать заспала младенца* — йоклаганда анасы баласын ялгыш тончыктырып үтергән; 2. йокыдан күзләр шешенү; күп йоклап шешенү.

**ЗАСПА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — озак йоклау.

**ЗАСПЕШИ'ТЬ** *сов. разг.* — ашыга башлау, кабалана башлау.
**ЗАСПИРТОВА'ТЬ** *сов.* — спиртлау.
**ЗАСПИРТО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. заспиртовать.
**ЗАСПИРТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — спиртлану.
**ЗАСПО'РИТЬ** *сов.* — бәхәсләшә башлау, сүз көрәштерә башлау.
**ЗАСПО'РИТЬСЯ** *сов. разг.* — сүз көрәштерү белән мавыгып китү.
**ЗАСПОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — үргемләнеп китү, кызып китү; *дело заспорилось* — эш үргемләнеп китте.
**ЗАСРАМИ'ТЬ** *сов. просторечь.* — оятка калдыру, адәм көлкесенә калдыру, хур итү.
**ЗАСТА'ВА** *ж.* — застава.
**ЗАСТАВА'ТЬ** *несов.* — к. застать.
**ЗАСТА'ВИТЬ** I *сов.* — 1. тутыру, тутырып бетерү; *заставить всю комнату мебелью* — бөтен бүлмәне мебель белән тутыру; 2. каплап кую; *заставить дверь шкафом* — ишекне шкаф белән каплап кую.
**ЗАСТА'ВИТЬ** II *сов.* — мәҗбүр итү, кушу; *заставить ждать* — көтәргә мәҗбүр итү. ◇ **Не заставить ждать себя** — көттермәү. **Не заставить просить себя** — ялындырмау.
**ЗАСТА'ВИТЬСЯ** *сов. разг.* — тулу, тулып бетү (мәсәлән, бүлмә мебель белән).
**ЗАСТА'ВКА** *ж.* — заставка (китап бите башындагы бизәк, орнамент).
**ЗАСТАВЛЯ'ТЬ** I *несов.* — к. заставить I.
**ЗАСТАВЛЯ'ТЬ** II *несов.* — к. заставить II.
**ЗАСТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. заставиться; 2. *страд.* тутырылу.
**ЗАСТА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. застояться.
**ЗАСТАРЕВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. застареть.
**ЗАСТАРЕ'ЛЫЙ** — күптәнге, иске, элекэлектән килгән; *застарелая болезнь* — күптәнге авыру; *застарелые привычки* — иске (элек-электән килгән) гадәтләр.
**ЗАСТАРЕ'ТЬ** *сов.* — искерү.
**ЗАСТА'ТЬ** *сов.* — туры китерү, күрү, очрату; *застал товарища дома* — иптәшемне өйдә туры китердем. ◇ **Я застал его за работой** — мин килгәндә (кергәндә) ул эшләп утыра иде. **Застать врасплох** — көтмәгәндә өстенә барып чыгу, көтмәгәндә килеп (барып) керү. **Я его уже не застал в живых** — мин барганда ул үлгән иде инде. **Застать в живых** — сәламәт чагында күрү.
**ЗАСТЁГИВАТЬ** *несов.* — к. застегнуть.
**ЗАСТЁГИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. застегнуться; 2. *страд.* төймәләнү, төймәләп куелу, каптырмалану, каптырмалап куелу.
**ЗАСТЕГНУ'ТЬ** *сов.* — төймәләү, каптыру, каптырмалау, төймәләп кую, каптырмалап кую.
**ЗАСТЕГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — к. застегнуть.
**ЗАСТЁЖКА** *ж.* — каптырма.
**ЗАСТЕКЛИ'ТЬ** *сов.* — пыяла куйдыру, пыяла кую.
**ЗАСТЕКЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. застеклить.
**ЗАСТЕКЛЯ'ТЬСЯ** *несов страд.* — пыяла куелу, пыяла куйдырылу.
**ЗАСТЕЛИ'ТЬ** *сов. просторечь.* — к. застлать 1.
**ЗАСТЕ'НОК** *м. истор.* — төрмә, зиндан.
**ЗАСТЕ'НЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — оялучанлык, тартынучанлык, кыюсызлык, базымсызлык.
**ЗАСТЕ'НЧИВЫЙ** — оялучан, тартынучан, кыюсыз, базымсыз.
**ЗАСТИГА'ТЬ** *несов.* — к. застичь.
**ЗАСТИЛА'ТЬ** *несов.* — к. застлать 1.
**ЗАСТИЛА'ТЬСЯ** *несов.* — к. застлаться 1.
**ЗАСТИ'ЛКА** *ж. мн.* нет — 1. җәю, түшәү; *застилка мостовой* — урамга таш түшәү; 2. җәелә торган әйбер (мәсәлән, палас); түшәлә торган әйбер (мәсәлән, салам).
**ЗАСТИРА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. юып алу, бер өлешен генә юу; *застирать рукав* — җиңне юу; *застирать пятно* — тапны юу; 2. юып бозу; *застирать платье* — күлмәкне юып бозу.
**ЗАСТИ'РЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. застирать 1.
**ЗАСТИ'РЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — юылып алыну, юып бетерелү (мәсәлән, тап).
**ЗАСТИ'ЧЬ** *сов.* — өстенә барып чыгу, көтмәгәндә барып чыгу; *застичь на месте преступления* — җинаять эшләп ятканда өстенә барып чыгу. ◇ **Дождь застиг нас в поле** — кырда чакта без яңгырга эләктек. **Нас застигла гроза** — без яшенле яңгырга эләктек.
**ЗАСТЛА'ТЬ** *сов.* — 1. җәю; *застлать пол ковром* — идәнгә ковёр җәю; 2. *перен.* каплап алу, каплау, томалау; *дым застлал небо* — төтен күкне каплады.
**ЗАСТЛА'ТЬСЯ** *сов.* — каплану, томалану; *небо застлалось дымом* — күк төтен белән капланды.
**ЗАСТО'Й** *м. мн.* нет — 1. торгынлык, тоткарлык, сүлпәнлек; *застой в торговле* — сәүдәдә торгынлык; 2. *мед.* туктау, тукталу; *застой крови* — кан туктау, кан йөрешенен тукталуы.
**ЗАСТО'ЙНЫЙ** — 1. *мед.* тукталган, туктап калган; *застойная кровь* — туктап калган кан; 2. үтмәс, үтемсез; *застойный товар* — үтмәс товар.
**ЗАСТО'ЛЬНЫЙ** — табында ...-а торган; *застольные разговоры* — табында сөйләнә торган сүзләр; *застольная песня* — табында җырлана торган җыр.
**ЗАСТОНА'ТЬ** *сов.* — ыңгыраша башлау.
**ЗАСТО'ПОРИВАТЬ** *несов.* — к. застопорить.
**ЗАСТО'ПОРИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. застопориться; 2. *страд.* туктатылу.
**ЗАСТО'ПОРИТЬ** *сов.* — туктату.
**ЗАСТО'ПОРИТЬСЯ** *сов.* — туктау.
**ЗАСТОЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*долго простоять*) озак тору, озак вакыт тик тору; 2. озак торып бозылу; *вода застоялась* — су озак торып бозылган.
**ЗАСТРА'ИВАТЬ** *несов.* — к. застроить 1.

**ЗАСТРА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. застроиться 1.

**ЗАСТРАХОВА'ТЬ** *сов.* — 1. страховать итү; *застраховать дом* — өйне страховать итү; 2. *перен.* алдан саклану чарасын күрү.

**ЗАСТРАХОВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. үзен страховать итү; 2. *перен.* саклану чарасын күреп кую.

**ЗАСТРАХО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. застраховать.

**ЗАСТРАХО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. застраховаться; 2 *страд.* страховать ителү.

**ЗАСТРА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. застрочить 1.

**ЗАСТРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — каелып бетү.

**ЗАСТРАЩА'ТЬ** *сов.*, **ЗАСТРА'ЩИВАТЬ** *несов. просторец.* — к. запугать.

**ЗАСТРЕВА'ТЬ** *несов.* — к. застрять.

**ЗАСТРЕ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. застрелить.

**ЗАСТРЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. застрелиться; 2 *страд.* атып үтерелү.

**ЗАСТРЕЛИ'ТЬ** *сов.* — атып үтерү.

**ЗАСТРЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — атылып үлү, үз-үзен атып үтерү.

**ЗАСТРЕ'ЛЬЩИК** *м.*, **ЗАСТРЕ'ЛЬЩИЦА** *ж.* — башлап җибәрүче, инициатор; *застрельщик соцсоревнования* — социалистик ярышны башлап җибәрүче.

**ЗАСТРЕЛЯ'ТЬ** *сов. разг.* — ата башлау.

**ЗАСТРИГА'ТЬ** *несов. разг.* — к. застричь 2.

**ЗАСТРИГА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — төптән (эчкәртен) киселү (тырнак турында).

**ЗАСТРИ'ЧЬ** *сов. разг.* — 1. кырка башлау (йонны); кисә башлау (тырнакны); 2. төптән кисү, эчкәртен кисү (тырнакны).

**ЗАСТРОГА'ТЬ** *сов.* — 1. (*начать строгать*) струклый башлау; 2. струклап очлау (такта яки таяк башын).

**ЗАСТРО'ИТЬ** *сов.* — 1. биналар салу, каралтылар салу; *застроить домами свободный участок земли* — буш яткан җиргә өйләр салу; 2. (*начать строить*) сала башлау, төзи башлау (йорт һәм башка каралтылар).

**ЗАСТРО'ИТЬСЯ** *сов.* — 1. төзелү, салыну; 2. (*начать строиться*) төзелә башлау, салына башлау.

**ЗАСТРО'ЙЩИК** *м.* — төзүче, коручы.

**ЗАСТРОЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*на швейной машине*) каю, каеп чыгу; 2. (*начать быстро писать*) тиз-тиз генә яза башлау, сызгалый башлау; 3. (*из пулемёта, автомата*) ата башлау.

**ЗАСТРУИ'ТЬСЯ** *сов.* — ага башлау.

**ЗАСТРЯ'ТЬ** *сов.* — 1. утыру, кереп калу; кадалу, кадалып калу; *пуля застряла в кости* — пуля сөяккә кереп калган; *кость застряла в горле* — тамакка сөяк утырды; 2. батып калу, бату; *колесо застряло в грязи* — тәгәрмәч пычракка батты; 3. *перен.* тотылып калу, тоткарланып калу, батып калу; *дело застряло в канцелярии* — эш канцеляриядә тоткарланып калды; 4. *перен.* китеп югалу, китеп бату; *где ты застрял?* — кая китеп югалдың? Кая китеп баттың?

**ЗАСТУДИ'ТЬ** *сов. разг.* — салкын тидерү; *застудить горло* — тамакка салкын тидерү.

**ЗАСТУДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — салкын тию, салкын тидерү.

**ЗАСТУ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. застудить.

**ЗАСТУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. застудиться.

**ЗА'СТУП** *м.* — тимер көрәк.

**ЗАСТУПА'ТЬ** *несов. устар.* — к. заступить.

**ЗАСТУПА'ТЬСЯ** *несов.* — к. заступиться.

**ЗАСТУПИ'ТЬ** *сов.* — урынын алу, (берәүнең) урынына калу, алыштыру, алмаштыру; *заступить место отца* — атасы урынына калу.

**ЗАСТУПИ'ТЬСЯ** *сов.* — яклау, яклап чыгу, арага керү; *заступиться за товарища* — иптәшне яклау.

**ЗАСТУ'ПНИК** *м.*, **ЗАСТУ'ПНИЦА** *ж.* — яклаучы, арага керүче.

**ЗАСТУ'ПНИЧЕСКИЙ** *устар.* — яклау ...-ы; *заступнические слова* — яклау сүзләре.

**ЗАСТУ'ПНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — яклау, яклап чыгу, арага керү.

**ЗАСТУЧА'ТЬ** *сов.* — шакылдата башлау, шакый башлау, дөбердәтә башлау.

**ЗАСТУЧА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. застучать.

**ЗАСТЫВА'ТЬ** *несов.* — к. застыть.

**ЗАСТЫДИ'ТЬ** *сов. разг.* — оялту.

**ЗАСТЫДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — оялу.

**ЗАСТЫ'НУТЬ** *сов. обл.* — к. застыть.

**ЗАСТЫ'ТЬ** *сов.* — 1. куеру, кату; *клей застыл* — җилем куерган; 2. *обл.* кату, туңу; *река застыла* — елга туңган; 3. *разг.* өшү; туңу; *я совсем застыл на морозе* — салкында мин бөтенләй өшедем; 4. *перен. книж.* катып калу; *застыть от удивления* — гаҗәпләнүдән катып калу; 5. *перен. книж.* (*погрузиться в застой*) торгынлык хәленә килү, катып калу.

**ЗАСУДИ'ТЬ** *сов. разг.* — гаепле дип табу, җәзага хөкем итү.

**ЗАСУЕТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ыгы-зыгы килә башлау, каушап калу; нишләргә белмичә әрле-бирле чабу; 2. ыгы-зыгы килеп хәлдән таю (ару).

**ЗАСУ'ЖИВАТЬ** *несов. просторец.* — к. засудить.

**ЗАСУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. просторец.* — гаепле дип табылу, җәзага хөкем ителү.

**ЗАСУ'НУТЬ** *сов.* — 1. тыгу, тыгып кую; *засунуть руки в карман* — кулларны кесәгә тыгу; 2. тыгып яшереп кую; салып кую; *засунуть нужные документы в портфель* — кирәкле документларны портфельгә салып кую.

**ЗА'СУХА** *ж.* — корылык.

**ЗАСУХОУСТО'ЙЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — корылыкка чыдамлылык, корылыкка каршы торучанлык.

**ЗАСУХОУСТО'ЙЧИВЫЙ** *с.-х.* — корылыкка чыдамлы; корылыкка бирешмәүчән, корылыкка чыдам; *засухоустойчивые культуры* — корылыкка чыдам культуралар.

**ЗАСУ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*—к. засучить.

**ЗАСУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — сызганылу, кайтарып куелу.

**ЗАСУЧИ'ТЬ** *сов. разг.* — сызгану, сызганып кую; *засучить рукава* — җиңнәрне сызгану.

**ЗАСУ'ШИВАТЬ** *несов.* — к. засушить.

**ЗАСУ'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. засушиться; 2. *страд.* киптерелү.

**ЗАСУШИ'ТЬ** *сов.* — киптерү.

**ЗАСУШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кибү.

**ЗАСУ'ШЛИВЫЙ**—коры, явым-төшемсез; корылык була торган; *засушливый год* — коры ел, явым-төшемсез ел; *засушливая местность* — корылык була торган урын.

**ЗАСЧИТА'ТЬ** *сов.* — 1. (кертеп) исәпләү; хисабына кертү; *засчитать в счёт долга* — бурыч хисабына кертеп исәпләү; 2. *разг.* саный башлау.

**ЗАСЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. засчитать 1.

**ЗАСЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— (кертеп) исәпләнү, хисабына кертелү.

**ЗАСЫЛА'ТЬ** *несов.*— к. заслать.

**ЗАСЫЛА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җибәрелү.

**ЗАСЫ'ПАТЬ** *сов.*— 1. күмү, күмеп тигезләү; *засыпать яму* — чокырны күмү (күмеп тигезләү); 2. *перен.* яудыру; *засыпать вопросами* — сораулар яудыру; 3. салу; *засыпать чаю* — чәй салу; 4. сибә башлау, тутыра башлау. ◇ **Глаза засыпало песком** — күзләргә ком тулды.

**ЗАСЫПА'ТЬ** I *несов.*— к. заснуть.

**ЗАСЫПА'ТЬ** II *несов. разг.*— к. заспать.

**ЗАСЫПА'ТЬ** III *несов.* — к. засы́пать 1, 2, 3.

**ЗАСЫ'ПАТЬСЯ** I *сов.* — 1. керен тулу; *песок засыпался в сапоги* — итек эченә ком керен тулды; 2. каплану; *дорожка засыпалась сухими листьями* — юл коры яфраклар белән капланган.

**ЗАСЫ'ПАТЬСЯ** II *сов. разг. вульг.*— тотылу, эләгү, кабу.

**ЗАСЫПА'ТЬСЯ** I *несов. разг.* — к. заспаться.

**ЗАСЫПА'ТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. засы́паться I; 2. *страд.* күмелү, күмеп тигезләнү.

**ЗАСЫПА'ТЬСЯ** III *несов. просторечь. вульг.*— к. засы́паться II.

**ЗАСЫХА'ТЬ** *несов.*— к. засохнуть.

**ЗАТАВРИ'ТЬ** *сов. спец.*— тамга салу, келәймә салу.

**ЗАТАЁННЫЙ**—яшерен, яшерелгән, яшереп сакланган; сер итеп сакланган; *затаённые мечты* — сер итеп сакланган хыяллар. ◇ **Затаённое дыхание** — акрын гына сулыш алу. **Слушать с затаённым дыханием** — тын да алмыйча тыңлау. **Затаённый говор** — шыпырт кына сөйләшү.

**ЗАТА'ИВАТЬ** *несов.*— к. затаить.

**ЗАТА'ИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. затаиться; 2. *страд.* сакланылу.

**ЗАТАИ'ТЬ** *сов.*— саклау; *затаить злобу* — ачу саклау; *затаить обиду в душе* — күңелдә үпкә саклау. ◇ **Затаить дыхание** — тын да алмыйча тору.

**ЗАТАИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — посу, качу. ◇ **Затаиться в себе** *разг.* — кайгыны яшерү (рухи кичерешләрне сер итеп саклау).

**ЗАТА'ЛКИВАТЬ** *несов.* — к. затолкать 1 и затолкнуть.

**ЗАТА'ЛКИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— этеп кертелү, төртеп кертелү; этеп-төртеп кертелү.

**ЗАТАНЦЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — танцевать итә башлау, бии башлау.

**ЗАТА'ПЛИВАТЬ** *несов.*— к. затопить I (1 мәгънәсендә).

**ЗАТА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. затопиться I; 2. *страд.* ягып җибәрелү, кабызып җибәрелү.

**ЗАТА'ПТЫВАТЬ** *несов.*— к. затоптать 1.

**ЗАТА'ПТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— таптап тигезләнү (мәсәлән, эз); таптап батырылу (берәр әйбер балчыкка).

**ЗАТА'СКАННЫЙ** *разг.* — 1. таушалган, туздырылган, киеп туздырылган; *затасканный костюм* — киеп туздырылган костюм; 2. *перен. (банальный)* күп кабатланып тәме (кызыгы) җибәрелгән; күп чәйнәлгән; 3. (бер урыннан икенче урынга йөртеп) алҗытып бетерелгән, интектереп бетерелгән.

**ЗАТАСКА'ТЬ** *сов.* — 1. таушалдыру, таушалдырып бетерү, туздыру, туздырып бетерү; *затаскать пальто* — пальтоны таушалдырып (туздырып) бетерү; 2. *перен. (сделать избитым)* күп кабатлап тәмен (кызыгын) җибәрү; 3. *(измучить)* алҗытып бетерү, интектереп бетерү.

**ЗАТАСКА'ТЬСЯ** *сов. просторечь.*— 1. *(начать таскаться)* сөйрәлеп йөри башлау, тырай тибеп йөри башлау; 2. *(стать истрёпанным)* таушалу, тузу.

**ЗАТА'СКИВАТЬ** I *несов.*— к. затаскать.

**ЗАТА'СКИВАТЬ** II *несов. разг.* — к. затащить.

**ЗАТА'СКИВАТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. затаскаться 2; 2. *страд.* таушалдырылу, туздырылу; тәме (кызыгы) җибәрелү; алҗытып бетерелү, интектереп бетерелү.

**ЗАТА'СКИВАТЬСЯ** II *несов. страд. разг.*— өстерәп кертелү, сөйрәп кертелү.

**ЗАТА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. заточить II (1 мәгънәсендә).

**ЗАТА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— үткенләндерелү, кайралу, очлану.

**ЗАТАЩИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. өстерәп алып китү, өстерәп алып керү; *затащить лестницу в сад* — баскычны бакчага өстерәп алып керү; 2. *(привести куда-н.)* алып керү (иартеп, көчләп, үтенеп).

**ЗАТВЕРДЕВА'ТЬ** *несов.*— к. затвердеть.

**ЗАТВЕРДЕ'ЛЫЙ** *разг.* — каты, каткан, катып калган; *затвердела опухоль* — каты шеш.

**ЗАТВЕРДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. затвердеть; 2. *мед.* *(опухоль)* каты шеш, катып калган урын.

**ЗАТВЕРДЕ'ТЬ** *сов.*— кату, катылану, катып калу.

**ЗАТВЕРДИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. яттан бикләү; *затвердить стихи* — шигырьне яттан бикләү; 2. *(начать твердить)* кабатлый башлау, кат-кат тукый башлау, бернәрсәне чәйни башлау.

**ЗАТВО'Р** *м.*—1. *(действие)* к. затворить I; 2. затвор; *затвор винтовки* — винтовка затворы; 3. *обл. (засов, запор)* бик; 4. *(у плотины)* япкыч.

**ЗАТВОРИ'ТЬ I** *сов.*— ябу, ябып кую.

**ЗАТВОРИ'ТЬ II** *сов.*— изү, изеп кую.

**ЗАТВОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ябылу; *окно затворилось* — тәрәзә ябылды; 2. бикләнеп утыру; бикләнеп яшәү; *он затворился в своём кабинете* — ул үзенең кабинетында бикләнеп утыра.

**ЗАТВО'РКА** *ж. обл.* — бик, келә, эшермә.

**ЗАТВОРЯ'ТЬ** *несов.*— к. затворить I.

**ЗАТВОРЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. затвориться.

**ЗАТЕВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. затеять.

**ЗАТЕВА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. затеяться; 2. *страд.* башлап җибәрелү; корылу, уйлап чыгарылу.

**ЗАТЕ'ЙЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. кыланучанлык, хикмәтлелек; 2. *(занимательность)* кызыклылык, мәзәклелек.

**ЗАТЕ'ЙЛИВЫЙ** — 1. әкәмәт, хикмәтле; *затейливое украшение* — әкәмәт бизәк; *затейливая речь* — хикмәтле речь; 2. кызыклы; *затейливая игрушка* — кызыклы уенчык; 3. *устар.* тапкыр; *затейливый ум* — тапкыр акыл.

**ЗАТЕ'ЙНИК** *м.*, **ЗАТЕ'ЙНИЦА** *ж. разг.*— 1. *(забавник)* мәзәкче; 2. *(инициатор, руководитель игры)* затейник, уеннар оештыручы.

**ЗАТЕ'ЙНЫЙ** *просторечи.* — к. затейливый.

**ЗАТЕ'ЙЩИК** *м. разг.* — башлап җибәрүче.

**ЗАТЕКА'ТЬ** *несов.*— к. затечь.

**ЗАТЕ'М** — 1. *(потом)* аннан соң, аннары; 2. *устар. (поэтому)* шуңа күрә, шуңлыктан, шуның өчен. ◇ **Затем, что** *союз* — чөнки. **Затем, чтобы** — өчен; *а я затем и пришёл, чтобы вам помочь* — мин сезгә ярдәм итү өчен килдем дә.

**ЗАТЕМНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(действие)* к. затемнить; 2. *мед.* кара тап; *затемнение в лёгких* — үпкәдәге кара тап; 3. *разг.* томанлану; *затемнение ума* — акыл томанлану.

**ЗАТЕМНЕ'ТЬ** *сов.* — каралып күренә башлау; *что-то затемнело впереди* — алда нәрсәдер каралып күренә башлады. ◇ **Затемнело в глазах** — күз алларым караңгылачып китте.

**ЗАТЕМНЕ'ТЬСЯ** *сов.*— к. затемнеть.

**ЗАТЕМНИ'ТЬ** *сов.* —1. *(сделать тёмным)* каралту; 2. караңгылау, караңгыландыру; *затемнить город* — шәһәрне караңгыландыру; 3. *перен.* томаландыру, томалау; *затемнить сознание* — аңны томаландыру.

**ЗАТЕМНИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. каралу; 2. *перен.* томалану; *сознание затемнилось* — аң томаланды.

**ЗА'ТЕМНО** *нареч. разг.* — караңгыда, караңгы чакта, караңгы белән, яктырганчы, яктырмас борын.

**ЗАТЕМНЯ'ТЬ** *несов.*— к. затемнить.

**ЗАТЕМНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. затемниться; 2. *страд.* караңгыландырылу; каралтылу; томаландырылу.

**ЗАТЕНИ'ТЬ** *сов.*— күләгәләү, ышыклау, күләгә төшерү.

**ЗАТЕНЯ'ТЬ** *несов.*— к. затенить.

**ЗАТЕНЯ'ТЬСЯ** *сов. страд.*— күләгәләнү, күләгә төшерелү.

**ЗАТЕПЛИ'ТЬ** *сов. поэт.* — кабызып җибәрү, яндырып җибәрү; *затеплить свечку* — шәм кабызып җибәрү.

**ЗАТЕПЛИ'ТЬСЯ** *сов. поэт.*— яна башлау; җемелди башлау; *затеплилась звезда на небе* — күктә йолдыз җемелди башлады.

**ЗА'ТЕПЛО** *нареч. обл.* — җылы чакта, җылы вакытта, салкыннар башланганчы.

**ЗАТЕПЛЯ'ТЬ** *несов. обл.*— к. затеплить.

**ЗАТЕРЕБИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. тарткалый башлау, йолыккалый башлау. 2. тарткалап йөдәтеп бетерү; *дети меня совсем затеребили* — балалар мине тарткалап йөдәтеп бетерделәр.

**ЗАТЕРЕ'ТЬ** *сов.*— 1. ышкып бетерү; сөртеп бетерү; буяу белән каплау, өстеннән буяп бетерү; *затереть надпись на стене* — стенадагы язуны ышкып бетерү; *затереть краской рисунок* — рәсемне өстеннән буяп бетерү; 2. кысу; *в толпе меня затёрли* — мине халык төркеме арасына кертеп кыстылар; 3. *перен.* кыерсыту, юл бирмәү, кысу; *молодого специалиста пытались затереть* — яшь белгечне кыерсытырга маташканнар иде; 4. таушалдыру, таушалдырып бетерү; туздыру; *затереть салфетку* — тастымалны туздырып бетерү.

**ЗАТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — тыкшыну, кысылып керү, кысыла-кысыла керү; *затереться в толпу* — кысыла-кысыла халык арасына керү.

**ЗАТЕРЗА'ТЬ** *сов. разг.*— азаплап бетерү, җәфалап бетерү, интектереп бетерү.

**ЗАТЕ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. затерять.

**ЗАТЕ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. затеряться.

**ЗАТЕ'РЯННЫЙ** — 1. югалган; 2. *перен.* онытылган, игътибарсыз калдырылган, читкә кагылган, читләтелгән; *он не чувствует себя затерянным* — ул үзен читкә кагылган итеп хис итми.

**ЗАТЕРЯ'ТЬ** *сов. разг.*— югалту, каядыр кую; *я затерял ножницы* — кайчыны каядыр куйганмын.

**ЗАТЕРЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. югалу; *книга затерялась* — китап югалды; 2. *перен.* кереп югалу, югалып калу; *затеряться в толпе* — халык арасына кереп югалу.

**ЗАТЕСА'ТЬ** *сов.*— 1. юнып алу, юна төшү, очлау, очлый төшү; *затесать доску* — тактаны юна төшү; 2. *(начать тесать)* юна башлау.

**ЗАТЕСА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — тыкшыну, тыкшынып керү (тиеш булмаган урынга).

**ЗАТЕСНИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. кысу, кысып кертү; 2. *перен. простореч. (сильно притеснить)* кыерсыту, җәберләү.

**ЗАТЕСНЯ'ТЬ** *несов. разг.*— к. затеснить.

**ЗАТЕСНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— 1. кысылу, кысып кертелү; 2. *перен.* кыерсытылу, җәберләнү.

**ЗАТЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. агып керү, саркып керү, керү; *вода затекла в чулан* — чоланга су агып кергән; *во время купанья вода затекла в уши* — су коенганда колакка су керде; 2. шешү, кан саву, бүртеп чыгу, шешенү; *от сильного ушиба глаз затёк*— каты бәрелүдән күзе шешкән; 3. оюү; *нога затекла* — аягым оеды.

**ЗАТЕ'Я** *ж.*— 1. ният, эш; *нелепая затея* — мәгънәсез эш; 2. мәзәк, шуклык, шаянлык; *ребячьи затеи* — балалык шаянлыклары. ◇ **Попросту, без затей** — экәмәт кормыйча гына.

**ЗАТЕ'ЯТЬ** *сов. разг.*— 1. уйлау, башлау, ниятләү, башлап җибәрү; *затеяли сыграть квартет* — квартет уйнарга уйладылар; 2. *(устроить)* кору, корып җибәрү, башлап җибәрү, уйлап чыгару.

**ЗАТЕ'ЯТЬСЯ** *сов. разг.* — башланып китү; *затеялось дело* — эш башланып китте.

**ЗАТИРА'НИТЬ** *сов. простореч.* — җәфалау, җәфалап бетерү; җәберләү, җәберләп бетерү.

**ЗАТИРА'ТЬ** *несов.*— к. затереть.

**ЗАТИРА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. затереться; 2. *страд.* ышкып бетерелү, сөртеп бетерелү; буяу белән каплану; кысылу; кыерсытылу, кимсетелү, җәберләнү.

**ЗАТИ'СКАТЬ** *сов. разг.* — 1. кысып интектереп бетерү, азаплап бетерү; 2. *(начать тискать)* кыса башлау.

**ЗАТИ'СКИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. затиснуть.

**ЗАТИ'СКИВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— 1. к. затиснуться; 2. *страд.* кысып кертелү, төртеп кертелү, этеп-төртеп кертелү.

**ЗАТИ'СНУТЬ** *сов. простореч.* — кысып кертү, төртеп кертү, этеп-төртеп кертү.

**ЗАТИ'СНУТЬСЯ** *сов. простореч.* — кысылып керү; *затиснуться в толпу* — халык арасына кысылып керү.

**ЗАТИХА'ТЬ** *несов.*— к. затихнуть.

**ЗАТИ'ХНУТЬ** *сов.* — 1. тыну, тынып калу; *звуки затихли* — тавышлар тынды; 2. акрынаю, сүрелү; басылу; *дождь затих* — яңгыр басылды; 3. *перен.* тынычлану, тукталу (сүздән, хәрәкәттән); *больной затих*— авыру тынычланды.

**ЗАТИ'ШЬЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. тынлык, тынычлык, басылып тору, тынып тору; *затишье перед грозой* — яшенле яңгыр алдындагы тынлык; *затишье после боя* — сугыштан соң тынып тору; 2. *(на море)* штиль, җилсезлек.

**ЗАТКА'ТЬ** *сов.* — 1. *(покрыть тканым узором)* чүпләмләп чигү; 2. *разг. (начать ткать)* тукый башлау, суга башлау.

**ЗАТКА'ТЬСЯ** *сов.*— чүпләмләп чигелү.

**ЗАТКНУ'ТЬ** *сов.* — 1. тыгу, тыгып кую; *заткнуть уши ватой* — колакка мамык тыгып кую; 2. кыстыру, кыстырып кую; *заткнуть за пояс* — билбауга кыстырып кую. ◇ **Заткнуть рот (глотку)** *перен. простореч. вульг.* — авызын томалау, сүз әйтергә ирек бирмәү. **Заткни глотку!** *простореч. вульг.*— күп лыгырдама, авызыңны яп. **Заткнуть за пояс** *разг.*— уздырып җибәрү (берәүдән), өстен чыгу.

**ЗАТЛЕ'ТЬ** *сов.* — 1. чери башлау, кыза башлау; *навоз затлел* — тирес чери башлаган; 2. пыскып яна башлау; *сырые дрова затлели* — чи утын пыскып яна башлады.

**ЗАТЛЕ'ТЬСЯ** *сов.*— к. затлеть.

**ЗАТМЕВА'ТЬ** *несов. книж.*— к. затмить.

**ЗАТМЕВА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. затмиться; 2. *страд.* каплану, томалану, күләгәләнү.

**ЗАТМЕ'НИЕ** *ср.*— тотылу; *затмение луны* — ай тотылу. ◇ **На меня какое-то затмение нашло** — әллә нәрсә, минем зиһенем таралып китте.

**ЗАТМИ'ТЬ** *сов.*— 1. каплау, томалау; *тучи затмили всё небо* — болытлар бөтен күк йөзен каплаган; 2. *перен.* өстен чыгу, уздыру; *затмил всех своим остроумием* — сүзгә тапкырлыгы белән ул бөтен кешеләрдән дә уздырды.

**ЗАТМИ'ТЬСЯ** *сов.* — сүнү, тоныклану, карангылану.

**ЗАТО'** *союз противит. разг.*— аның каравы, ...-са да, эмма; *пришлось много мне поработать, зато задание выполнил* — күп эшләргә туры килде, аның каравы заданиене үтәдем.

**ЗАТОВА'РЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — товарның артык булуы, кирәгеннән артык товар җыелу.

**ЗАТОВА'РИВАТЬ** *несов.*— к. затоварить.

**ЗАТОВА'РИТЬ** *сов.*— кирәгеннән артык товар җыеп тоту (җыеп яткыру); *затоварить галантерею на складе* — складта кирәгеннән артык галантерея товарлары җыеп тоту.

**ЗАТОВА'РИТЬСЯ** *сов.*— сатылмыйча калу; җыелып калу, өелеп калу.

**ЗАТОЛКА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. төрткәләп авырттырып бетерү; эткәләп-төрткәләп хәлдән тайдыру; 2. *(начать толкать)* этә башлау, төрткәли башлау.

**ЗАТОЛКНУ'ТЬ** *сов. разг.* — этеп кертү, төртеп кертү, этеп-төртеп кертү.

**ЗАТОЛО'ЧЬ** *сов. разг.* — төя башлау, ваклый башлау.

**ЗАТОМИ'ТЬСЯ** *сов. обл.*— 1. өшәнү, йончу, алҗу, хәлсезләнү; *лошадь затомилась*— ат өшәнде; 2. *(начать томиться)* өшәнә башлау, алҗый башлау.

**ЗАТО'Н** *м.*— 1. *(залив)* затон, елга култыгы (пароходлар кышлый торган урын); 2. буа (балык тоту өчен).

**ЗАТОНУ'ТЬ** *сов.*— бату.

**ЗАТО'ПАТЬ** *сов. разг.* — аяк тибә башлау.

**ЗАТОПИ'ТЬ** I *сов.* — 1. ягып җибәрү; *затопить печку* — мичкә ягып җибәрү; 2. яга башлау; *в прошлом году затопили в октябре* — узган елны октябрьда яга башладык.

**ЗАТОПИ'ТЬ** II *сов.*— басу; *разлившаяся река затопила луга*— ташып чыккан елга болыннарны басты.

**ЗАТОПИ'ТЬСЯ** I *сов. разг.*— ягыла башлау.

**ЗАТОПИ'ТЬСЯ** II *сов.* — су астында калу; *луга затопились* — болыннар су астында калды.

**ЗАТО'ПКА** *ж.*— **1.** к. затопить; **2.** чыра, йомычка (ягып җибәрү өчен кирәкле әйберләр).

**ЗАТОПЛЯ'ТЬ** I *несов. простореч.* — к. затопить I.

**ЗАТОПЛЯ'ТЬ** II *несов.*— к. затопить II.

**ЗАТОПЛЯ'ТЬСЯ** I *несов. простореч.*— к. затапливаться.

**ЗАТОПЛЯ'ТЬСЯ** II *несов.* — к. затопиться II.

**ЗАТОПТА'ТЬ** *сов.*— **1.** таптап тигезләү; таптап батыру (берәр нәрсәне йомшак җиргә); *затоптать следы* — эзне таптап тигезләү (югалту); **2.** таптап сүндерү; *затоптать горящую тряпку* — яна торган чүпрәкне таптап сүндерү; **3.** таптау, таптап үтерү; *лошадь затоптала курицу* — ат тавыкны таптап үтергән; **4.** *(испачкать)* таптаһ бетерү, таптап пычратып бетерү; **5.** *(начать топтать)* таптый башлау. ◇ **Затоптать в грязь** *разг.* — пычрак ату, яла ягу, кара ягу.

**ЗАТОПТА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — таптана башлау; *затоптаться на месте* — бер урында таптана башлау.

**ЗАТО'Р** *м.*— **1.** *(остановка, задержка в движении)* затор, тоткарлык; өелү; **2.** тыгылу; *затор льда* — боз тыгылу.

**ЗАТОРМОЗИ'ТЬ** *сов.*— **1.** *(начать тормозить)* тормозлый башлау; **2.** *(остановить тормозом)* тормозлау, тормозлап туктату; **3.** *перен.* тоткарлау, тоткарлык ясау, әкренәйтү; *затормозить дело*—эшне тоткарлау.

**ЗАТОРМОЗИ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** тормозлану, әкренәю (тормоз тәэсире белән); *поезд затормозился* — поезд тормозланды; **2.** *перен. (задержаться)* әкренәю, тоткарлану, туктала.

**ЗАТОРМОШИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. *(начать тормошить)* кабаландыра, ашыктыра башлау, тарткалый-йолыккалый башлау; **2.** *(утомить)* тарткалап-йолыккалап интектереп бетерү.

**ЗАТОРМОШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— **1.** кабалана башлау, ыгы-зыгы килә башлау; **2.** ыгы-зыгы килеп арып бетү.

**ЗАТОРОПИ'ТЬ** *сов. разг.*— ашыктыра башлау, кабаландыра башлау.

**ЗАТОРОПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ашыга башлау, кабалана башлау.

**ЗАТОСКОВА'ТЬ** *сов. разг.*— сагына башлау, ямансылый башлау, юксына башлау.

**ЗАТОЧА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. заточить I.

**ЗАТОЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.*— ябып куелу (төрмәгә, монастырьга).

**ЗАТОЧЕ'НИЕ** *ср. устар.*— **1.** ябу, ябып кую, сөрү; **2.** ябылуда булу, тоткында булу, сөргендә булу; **3.** төрмә, зиндан.

**ЗАТОЧИ'ТЬ** I *сов. устар.*— ябу, ябып кую; *заточить в тюрьму* — төрмәгә ябу.

**ЗАТОЧИ'ТЬ** II *сов.*— 1 *(начать точить)* очлый башлау; кайрый башлау, үткенли башлау; **2.** *(заострить)* үткенләү, кайрау.

**ЗАТОШНИ'ТЬ** *сов. разг.*— косасы килә башлау, күңел болгана башлау, укшыта башлау.

**ЗАТРАВИ'ТЬ** *сов.*— 1. *охот.* эт өстереп тоту, эттән тоттыру; *затравить зайца* — куянны эттән тоттыру; **2.** *перен. (замучить преследованиями)* эзәрлекләп теңкәсенә тию, эзәрлекләп җәфалап бетерү.

**ЗАТРА'ВЛИВАТЬ** *несов.*— к. затравить.

**ЗАТРА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. *охот.* эт өстереп тотылу; **2.** *перен.* эзәрлекләнү.

**ЗАТРА'ГИВАТЬ** *несов.*— к. затронуть.

**ЗАТРАПЕ'ЗНЫЙ** I *устар.*— аш-су арасында булган, табында булган; *затрапезная беседа* — аш-су арасында булган әңгәмә.

**ЗАТРАПЕ'ЗНЫЙ** II *разг.*— көндәлек, гади; *затрапезный халат* — көндәлек халат; *затрапезный вид* — гади кыяфәт.

**ЗАТРА'ТА** *ж.*— 1. к. затратить; **2.** *(затраченная сумма)* тотылган акча, расход.

**ЗАТРА'ТИТЬ** *сов.*— **1.** тоту, салу; *затратить средства на оборудование* — җиһазлар алуга средстволар тоту; **2.** *перен.* кую, түгү, салу, тыгу, сарыф итү; *затратить много труда и силы* — күп хезмәт һәм көч кую.

**ЗАТРА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. затратить.

**ЗАТРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— тотылу, салыну; куелу.

**ЗАТРЕ'БОВАТЬ** *сов.*— **1.** соратып алу, таләп итү; *затребовать справку* — белешмә соратып алу; **2.** чакыртып китертү, чакырту; *затребовать свидетелей* — шаһитларны чакырту.

**ЗАТРЕПА'ТЬ** *сов. простореч.*— **1.** туздырып бетерү, таушалдырып бетерү, аламаландырып бетерү; **2.** *перен. фам. (замучить)* интектереп бетерү, тинтерәтеп бетерү, җәфалап бетерү, йончытып бетерү; **3.** *(начать трепать)* селкетә башлау; тарткалый-йолыккалый башлау; йолка башлау, калтырата башлау. ◇ **Затрепать чьё-л. имя** — берәүнең исемен чәйнәү, берәү турында күп сөйләү.

**ЗАТРЕПА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— **1.** тузып бетү, таушалып бетү, тетелеп бетү; **2.** *перен. фам. (замучиться)* интегеп бетү, хәлдән таю, йончып бетү; **3.** җилферди башлау, селкенә башлау; *флаг затрепался из стороны в сторону* — флаг әле бер якка, әле икенче якка җилферди башлады.

**ЗАТРЕПЕТА'ТЬ** *сов.*— калтырый башлау, тетри башлау, дерелди башлау.

**ЗАТРЕПЕТА'ТЬСЯ** *сов. книж. устар.*— селкенә башлау, калтырый башлау.

**ЗАТРЁПЫВАТЬ** *несов. простореч.*— к. затрепать 1, 2.

**ЗАТРЕЩА'ТЬ** *сов.*— 1. чытырдый башлау, шыгырдый башлау; *лёд затрещал* — боз чытырдый башлады; *стул затрещал* — урындык шыгырдый башлады; 2. черелди башлау; *кузнечики затрещали* — чикерткәләр черелди башлады; 3. дыңгырдый башлау; *барабаны затрещали* — барабаннар дыңгырдый башлады; 4. *перен. разг.* (*начать болтать*) такылдый башлау.

**ЗАТРЕ'ЩИНА** *разг.*: **дать затрещину** — чалтыратып яңагына сугу (кундыру).

**ЗАТРО'НУТЬ** *сов.*— 1. тиеп китү, кагылу, кагылып китү; әләгү; *пуля затронула кость* — пуля сөяккә тиеп киткән; 2. *перен.* кагылу, кагылып үтү, кагылып китү, әйтеп үтү; *затронуть вопрос* — мәсьәләгә кагылып үтү.

**ЗАТРУБИ'ТЬ** *сов.*— быргы кычкырта башлау.

**ЗАТРУДНЕ'НИЕ** *ср.*— 1. комачау, кыенлык, читенлек, уңайсызлык, авырлык; *устранить затруднение* — кыенлыкны бетерү; 2. кыен хәл, авыр хәл; *вывести из затруднения* — авыр хәлдән чыгару; *выйти из затруднения* — кыен хәлдән чыгу.

**ЗАТРУДНЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — кыенлашканлык, читенләшкәнлек.

**ЗАТРУДНЁННЫЙ** — авыр, кыен, читен; *затруднённое дыхание* — авыр сулау.

**ЗАТРУДНИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — авыр хәлдә булу, кыенлык, кыен булу, авырлык, читенлек; *затруднительность его положения* — аның авыр хәлдә булуы.

**ЗАТРУДНИ'ТЕЛЬНЫЙ** — кыен, авыр, читен; *затруднительное положение* — кыен хәл, авыр хәл.

**ЗАТРУДНИ'ТЬ** *сов.*— 1. (*осложнить*) кыенлаштыру, читенләштерү, авырлаштыру; 2. кыен хәлдә калдыру, читен хәлгә кую; *этот вопрос затруднил гостя* — бу сорау кунакны кыен хәлдә калдырды. ◇ **Если вас не затруднит** — әгәр дә сезгә кыен булмаса.

**ЗАТРУДНИ'ТЬСЯ** *сов.*— кыенсыну, авырсыну, читенсенү.

**ЗАТРУДНЯ'ТЬ** *несов.*— к. затруднить.

**ЗАТРУДНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. затрудниться; 2. *страд.* кыенлаштырылу, читенләштерелү.

**ЗАТРУ'СИТЬ** *сов. разг.*— курка башлау, шүрли башлау, өркә башлау.

**ЗАТРУСИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. вак-вак кына юырта башлау; *лошадь затрусила* — ат вак-вак кына юырта башлады; 2. селкеп бушата башлау; *затрусить муку из мешка* — онны капчыктан селкеп бушата башлау.

**ЗАТРЯСТИ'** *сов.*— 1. селкетә башлау, дыңгырдата башлау; 2. дерелдәтә башлау, калтырата башлау; *его затрясло от лихорадки* — аны бизгәк калтырата башлады.

**ЗАТРЯСТИ'СЬ** *сов.*— (*что*) селкенә башлау; (*кто*) калтырана башлау, калтырый башлау; *затрястись всем телом* — бөтен гәүдә белән калтырана башлау.

**ЗАТУЖИ'ТЬ** *сов. разг.*— пошына башлау, көенә башлау, кайгыра башлау, хәсрәтләнә башлау.

**ЗАТУМА'НИВАТЬ** *несов.*— к. затуманить.

**ЗАТУМА'НИВАТЬСЯ** *несов.*— к. затуманиться.

**ЗАТУМА'НИТЬ** *сов.*— 1. (*покрыть туманом*) томан белән каплау; 2. *перен.* караңгылау, томалау; *затуманить смысл* — мәгънәне томалау. ◇ **Слёзы затуманили глаза** — күзләрне яшь каплады.

**ЗАТУМА'НИТЬСЯ** *сов.*— 1. томан белән каплану; *горизонт затуманился* — горизонт томан белән капланды; 2. *перен.* караңгылану, томалану, каплану; *взор затуманился* — күз аллары караңгыланды; *глаза затуманились слезами* — күзләр яшь белән капланды.

**ЗАТУПИ'ТЬ** *сов.*—1. (*о лезвии*) үтмәсләү, үтмәсләндерү, кыршылдыру, йөзен кайтару; 2. (*об остроконечном предмете*) очсызландыру, очын бетерү.

**ЗАТУПИ'ТЬСЯ** *сов.*— үтмәсләнү; йөзе кайту, кыршылу; очы бетү.

**ЗАТУПЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. затупить.

**ЗАТУПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. затупиться.

**ЗАТУХА'ТЬ** I *несов.*— к. затухнуть I.

**ЗАТУХА'ТЬ** II *несов. обл.*— к. затухнуть II.

**ЗАТУ'ХНУТЬ** I *сов.*— 1. (*потухнуть*) сүнү; 2. *перен.* тукталу, басылу, сүнү; *колебания радиоволн затухли* — радиодулкыннарның тирбәлүе басылды.

**ЗАТУ'ХНУТЬ** II *сов. обл.*— исләнү, сасу.

**ЗАТУШЕВА'ТЬ** *сов.*— 1. тушь белән каплау; каралту; *затушевать теневые стороны предметов на рисунке* — рәсемгә төшерелгән әйберләрнең күләгәле якларын каралту; 2. *перен.* томалау, каплау, яшерү, томалап калдыру; *он старался затушевать его ошибку* — ул аның ялгышын томалап калдырырга тырышты.

**ЗАТУШЁВЫВАТЬ** *несов.*— к. затушевать.

**ЗАТУШИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. сүндерү; *затушить свечу* — шәмне сүндерү; 2. *перен. книж.* (*заглушить, подавить*) бастыру, томалау.

**ЗА'ТХЛОСТЬ** *ж. мн.* нет— 1. тынчулык, тынчыганлык; сөрсегәнлек; 2. *перен.* черeклек, бозыклык; черек булу, бозык булу.

**ЗА'ТХЛЫЙ** — 1. тынчу, тынчыган; *затхлый воздух* — тынчу һава; 2. күгәргән, сөрсегән, каксыган; *затхлая крупа* — күгәргән ярма; *затхлое масло* — сөрсегән май; 3. *перен.* черек, бозык; *затхлая среда* — черек среда, бозык среда; *затхлая атмосфера* — черек атмосфера.

**ЗАТЫ'КАТЬ** *сов. разг. фам.*— төртә башлау (бармак белән).

**ЗАТЫКА'ТЬ** *несов.*— к. заткнуть.

**ЗАТЫ'ЛОК** *м.*— баш арты, баш чүмечe. ◇ **Становиться в затылок** *разг.*— бер-бер артлы тезелү.

**ЗАТЫ'ЧКА** *ж. простореч.*— 1. (*действие*) к. заткнуть; 2. бөке, тыкқыч.

**ЗАТЮКОВА'ТЬ** *сов.*— төреп бәйләү, тюклап бәйләү.

**ЗАТЮКО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. затюковать.

**ЗАТЮКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— төреп бәйләнү, тюклап бәйләнү.

**ЗАТЯ'ГИВАТЬ** *несов.*— к. затянуть.

**ЗАТЯ'ГИВАТЬСЯ** *несов.*— к. затянуться.

**ЗАТЯЖЕЛЕ'ТЬ** *сов. простореч. обл.*— авырга калу, авырга узу, йөккә узу, балага узу.

**ЗАТЯ'ЖКА** *ж.*— 1. (*при курении*) эчкә суыру, эчкә тарту, эчкә алу; 2. *простореч.* озакка сузу, озакка сузылу, озакка тартылу; *затяжка дела* —эшне озакка сузу; 3. (*замедление в наступлении*) соңга калу, кичегү.

**ЗАТЯЖНО'Й** — озакка сузылган, озакка тартылган; *затяжная болезнь* — озакка сузылган авыру. ◇ **Затяжной прыжок** — парашютны озак ачмыйча төшү (парашютны җиргә якынлашканда гына ачу).

**ЗАТЯНУ'ТЬ** *сов.*— 1. тартып бәйләү; тарттырып бәйләү; *затянуть чемодан ремнём* — чемоданны каеш белән тарттырып бәйләү; 2. тартып тоту, нык тоту; *затянуть поводья* — тезгенне тартып тоту; 3. суырып алу, тартып алу; *болото затянуло корову* — сазлык сыерны суырып алды; 4. *разг.* (*завлечь*) кызыктырып кертү, кызыктырып тарту (берәүне берәр эшкә); 5. каплау, томалау, томалап алу; *тучи затянули небо* — болытлар күк йөзен томаладылар; 6. *безл.* каплану, бетәшү; *рану затянуло* — яра бетәште (төзәлде); 7. *разг.* озакка сузу; *затянуть дело* —эшне озакка сузу; 8. *разг.* (*запеть*) җырлый башлау, җырлап җибәрү, сузып җырлап җибәрү.

**ЗАТЯНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. тартып бәйләү, тарттырып бәйләү; *затянуться кушаком* — билбауны тартып бәйләү; 2. (*туго завязаться*) бәйләнү, нык бәйләнү; 3. каплану, томалану; *небо затянулось тучами* — күк йөзе болытлар белән капланды; 4. бетәшү; тартылу; *рана затянулась* — яра бетәште; 4. *разг.* озакка сузылу, озакка тартылу; *дело затянулось* — эш озакка сузылды; 5. (*втянуть в себя табачный дым*) эчкә суыру, эчкә тарту, эчкә алу.

**ЗАУ'МНИЧАТЬ** *сов. разг.*— акыл сата башлау.

**ЗАУ'МНЫЙ** — мәгънәсез, аңлаешсыз; *заумные стихи* — мәгънәсез шигырьләр; *заумные слова* — аңлаешсыз сүзләр.

**ЗАУ'МЬ** *ж. мн.* нет — мәгънәсез әсәр.

**ЗАУНЫ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— моңлылык, ямансулык.

**ЗАУНЫ'ВНЫЙ** *книж.*— моңлы, ямансу; *заунывная песня* — моңлы җыр.

**ЗАУПРЯ'МИТЬСЯ** *сов. разг.*— карыша башлау, киреләнә башлау, кәҗәләнә башлау.

**ЗАУРЯ'ДНЫЙ** *книж.*— гади, уртача; *заурядный писатель* — уртача язучы.

**ЗАУСЕ'НЕЦ** *м.*, **ЗАУСЕ'НИЦА** *ж.*—1. (*на пальцах*) эт тырнагы, шайтан тырнагы (тырнак янында купкан тире); 2. (*на металле*) металл кылчыгы (металлны кырганда өскә каерылып калган кылчык).

**ЗАУ'ТРА** *нареч. книж. поэт. устар.*— иртәгә иртә белән.

**ЗАУТЮ'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. заутюжить.

**ЗАУТЮ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— к. заутюжиться.

**ЗАУТЮ'ЖИТЬ** *сов.*— үтүкләү, үтүкләп кую.

**ЗАУТЮ'ЖИТЬСЯ** *сов.*— үтүкләнү, үтүкләп куелу.

**ЗАУ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. заучить.

**ЗАУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. заучиться; 2. *страд.* өйрәнелү, күңелдән бикләнү, ятлану.

**ЗАУЧИ'ТЬ** *сов.*— ятлау, бикләү.

**ЗАУЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. озак уку (уку йортында); 2. озак укудан ару, озак укып арып бетү.

**ЗАУША'ТЕЛЬСКИЙ** — тупас, хурлыклы; *заушательская критика* — тупас тәнкыйть, хурлыклы тәнкыйть.

**ЗАУША'ТЕЛЬСТВО** *ср.*— тупас тәнкыйть (кемнедер хурлауны максат итеп куйган тәнкыйть).

**ЗАУШИ'ТЬ** *сов. устар.*— 1. колак төбенә кундыру, колак төбенә утырту; 2. *перен.* (*оскорбить*) хурлау, мыскыл итү, мыскыллау.

**ЗАУ'ШНИЦА** *ж. мн.* нет — свинка авыруы (колак янындагы бизнең ялкынсынуы).

**ЗАФАНТАЗИ'РОВАТЬ** *сов. разг.*— фантазия кора башлау.

**ЗАФАНТАЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов. разг. ирон.*— хыялга чуму.

**ЗАФИКСИ'РОВАТЬ** *сов. книж.*— 1. (*отметить записью*) теркәп кую, язып кую; 2. (*окончательно установить*) беркетеп кую, ныгытып кую.

**ЗАФИЛОСО'ФСТВОВАТЬ** *сов. разг.*— фәлсәфә сата башлау.

**ЗАФИЛОСО'ФСТВОВАТЬСЯ** *сов. разг. ирон.*— фәлсәфә сатып ахмаклыкка барып җитү.

**ЗАФРАХТОВА'ТЬ** *сов. мор. торг.*— фрахтовать итү, йөк ташу өчен яллау (корабльне).

**ЗАХА'ЖИВАТЬ** *многокр. разг.*— кергәләү, кергәләп йөрү; *захаживайте почаще!* — ешрак кергәләгез!

**ЗАХАНДРИ'ТЬ** *сов. разг.*— эч поша башлау.

**ЗАХА'ПАТЬ** *сов. простореч. вульг.*— басып алу, тотып алу, эләктереп алу; *захапать чужие деньги* — кеше акчасын басып алу.

**ЗАХА'РКАТЬ** *сов.*— 1. какыра (төкерә) башлау; *захаркать кровью* — кан төкерә башлау; 2. *простореч.* какырып (төкереп) пычрату, какырып пычратып бетерү.

**ЗАХА'ЯТЬ** *сов. простореч. вульг.*— 1. яманлап хур итү, адәм мәсхәрәсе итү, кеше көлкесенә калдыру; 2. (*начать хаять*) яманлый башлау, хурлый башлау.

**ЗАХВА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. захвалить.

**ЗАХВА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— артык макталу; артык мактап бозылу.

**ЗАХВАЛИ'ТЬ** *сов. разг.*— артык мактау, артык мактап җибәрү; артык мактап бозу; *молодого артиста захвалили* — яшь артистны артык мактап җибәрделәр.

**ЗАХВА'СТАТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. (*начать хвастаться*) мактанырга тотыну, мактана башлау; 2. артык мактану, артык мактанып, ахмаклыкка барып җитү.

**ЗАХВА'Т** *м. мн.* нет — 1. басып алу, көчләп тартып алу, тартып алу; *захват чужих территорий* — чит территорияләрне басып алу; 2. *спорт.* тотып алу, учлап алу; *захват мяча* — тупны тотып алу.

**ЗАХВАТА'ТЬ** *сов. разг.*— кулдан кулга йөртеп пычрату, пычратып бетерү.

**ЗАХВАТИ'ТЬ** *сов.*— 1. алу; *захватить горсть орехов* — бер уч чикләвек алу; 2. эләктерү, эләктереп алу; *колесо машины захватило край халата* — машина тәгәрмәче халат кырыен эләктереп алды; 3. басып алу, тартып алу, алу; *захватить чужую территорию* — чит территорияне басып алу; *захватить в плен* — пленга алу; 4. чара күрү; *болезнь захватили вовремя* — авыруга каршы вакытында чара күрдек; 5. *перен.* үзенә тарту, җәлеп итү; нык кызыктыру, тәэсир итү; *революция захватила его целиком* — революция аны бөтенләй үзенә тартты; *эта книга захватила меня* — бу китап миңа нык тәэсир итте. ◇ **Захватило дух** (или **дыхание**) — тын бетте, тын кысылды. **Захватить дома** — өйдә туры китерү. **Захватить последний поезд** — соңгы поездга өлгерү. **Захватить врасплох** — көтмәгәндә өстенә барып чыгу. **Дождь захватил нас** — без яңгырга эләктек.

**ЗАХВА'ТНИЧЕСКИЙ** — басып алу ...-ы; *захватнические планы империалистов* — империалистларның басып алу планнары.

**ЗАХВА'ТЧИК** *м.*— илбасар, басып алучы.

**ЗАХВА'ТЫВАТЬ** I *несов.*— 1. к. захватить; 2. кызыксындыру, мавыктыру; *эта тема захватывает* — бу тема кызыксындыра.

**ЗАХВА'ТЫВАТЬ** II *несов. разг.*— к. захватать.

**ЗАХВА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. алыну; 2. басып алыну, тартып алыну.

**ЗАХВА'ТЫВАЮЩИЙ** — 1. эләктерә торган, эләктереп кыса торган, эләктереп тора торган; 2. *перен.* кызыклы, мавыктыргыч, үзенә тартучан; *захватывающий рассказ* — кызыклы хикәя. ◇ **Слушать с захватывающим интересом** — йотлыгып (бирелеп, кызыксынып) тыңлау.

**ЗАХВОРА'ТЬ** *сов. разг.*— авырый башлау.

**ЗАХИЛЕ'ТЬ** *сов. обл.*— хәлсезләнү, какшау, зәгыйфьләнү.

**ЗАХИРЕ'ТЬ** *сов.*— 1. (*о человеке*) бетеренү, бетерешү, ябыгу; 2. (*о растениях*) шиңү, кору, сулу; 3. *перен. книж.* сүнү, басылу, бетү; *талант его захирел* — аның таланты сүнде.

**ЗАХИХИ'КАТЬ** *сов. разг. фам.*— хихылдый башлау, хихылдап көлә башлау.

**ЗАХЛЕБНУ'ТЬ** *сов. разг.*— йотып җибәрү (сыек әйберне).

**ЗАХЛЕБНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. тончыгу (авызга су кереп тончыгу); *он захлебнулся* — авызына су кереп тончыкты; 2. *перен.* буыла язу, нишләргә белмәү, буылып үлә язу; *захлебнуться от злости* — ачуыннан нишләргә белмәү. ◇ **Захлебнуться от радости** — шатлыктан нишләргә белмәү, шатлыгы эченә сыймау. **Атака врага захлебнулась** — дошманның һөҗүме кире кайтарылды (уңышсызлыкка очрады).

**ЗАХЛЁБЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. захлебнуть.

**ЗАХЛЁБЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. захлебнуться. ◇ **Рассказывать, захлёбываясь** — йотлыга-йотлыга сөйләү. **Захлёбываться от смеха** — эче катып көлү. **Плакать, захлёбываясь** — үксеп-үксеп елау.

**ЗАХЛЕСНУ'ТЬ** *сов.*— 1. эләктерү, эләктереп алу; *захлеснуть петлей* — элмәк белән эләктереп алу; 2. китереп бәрү, бәреп керү; *волна захлеснула лодку* — дулкын көймәгә китереп бәрде. ◇ **Волна революции захлеснула широкие массы** — революция дулкыны киң массаны үзенә тартты.

**ЗАХЛЕСНУ'ТЬСЯ** *сов.*— эләгү, уралып эләгү.

**ЗАХЛЕСТА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (*засечь хлыстом*) камчылау, камчы белән кыйнау, камчы белән яру; камчылап үтерү; 2. (*начать хлестать*) камчы белән кыйный башлау. ◇ **Захлестал дождь** — яңгыр бик каты ява башлады.

**ЗАХЛЕСТНУ'ТЬ** *сов.*— к. захлеснуть.

**ЗАХЛЕСТНУ'ТЬСЯ** *сов.*— к. захлеснуться.

**ЗАХЛЁСТЫВАТЬ** I *несов.*— к. захлеснуть.

**ЗАХЛЁСТЫВАТЬ** II *несов. разг.*— к. захлестать.

**ЗАХЛО'ПАТЬ** *сов. разг.*— 1. кул чаба башлау; *публика захлопала артисту* — халык артистка кул чаба башлады; 2. шартлата башлау; *захлопать кнутом* — чыбыркы шартлата башлау.

**ЗАХЛО'ПНУТЬ** *сов.* — шап иттереп ябу, шап иттереп ябып кую; *захлопнуть дверь* — ишекне шап иттереп ябу. ◇ **Западня захлопнула птицу** — кош тозакка эләкте.

**ЗАХЛО'ПНУТЬСЯ** *сов.* — шап итеп ябылу.

**ЗАХЛОПОТА'ТЬ** *сов. разг.*— артыннан йөри башлау, хәстәрен күрә башлау.

**ЗАХЛОПОТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — (берәр эшнең) артыннан йөреп җәфаланып бетү, юллап йөри-йөри арып бетү (интегеп бетү).

**ЗАХЛО'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. захлопнуть.

**ЗАХЛО'ПЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. захлопнуться.

**ЗАХМЕЛЕ'ТЬ** *сов. разг.*— исерү.

**ЗАХНЫ'КАТЬ** *сов. разг. фам.* — сукраныpга тотыну, зарлана башлау.

**ЗАХО'Д** *м.* — 1. керү; 2. бату, баю; *заход солнца* — кояш бату (баю).

**ЗАХОДИ'ТЬ** I *несов.* — к. зайти.

**ЗАХОДИ'ТЬ** II *сов.* — йөри башлау.

**ЗАХОДИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — йөреп ару, йөри-йөри хәлдән таю.

**ЗАХО'ЖИЙ** *обл.* — читтән килгән; *захожий человек* — читтән килгән кеше.

**ЗАХОЛОДА'ТЬ** *сов. безл. обл.* — суыта башлау, суыклар башлану.

**ЗАХОЛОДЕ'ТЬ** *сов. просторечь.* — 1. туңу, туңып бетү; *весь захолодел от мороза* — салкыннан бөтенләй туңып беттем; 2. *безл.* суынып китү; *в воздухе захолодело* — һава суынып китте.

**ЗАХОЛУ'СТНЫЙ** — 1. аулак, тын, ерак (урын); 2. *перен. книж.* провинциаль, артта калган (культура ягыннан).

**ЗАХОЛУ'СТЬЕ** *ср.* — тын (аулак) урын, аулак почмак, ерак почмак.

**ЗАХОРОВО'ДИТЬ** *сов. просторечь.* — башын әйләндерү.

**ЗАХОРОНИ'ТЬ** *сов.* — 1. яшерү, табылмаслык итеп яшерү; 2. (*похоронить*) күмү, җирләү.

**ЗАХОТЕ'ТЬ** *сов.* — теләү, ...-сы килү; *захотеть пить* — эчәсе килү.

**ЗАХОТЕ'ТЬСЯ** *сов. безл.* — тели башлау, ...-сы килә башлау; *мне захотелось есть* — минем ашыйсы килә башлады.

**ЗАХОХОТА'ТЬ** *сов. разг.* — шаркылдап көлеп җибәрү, шаркылдап көлә башлау.

**ЗАХРАПЕ'ТЬ** *сов. разг.* — гырылдый (гырлый) башлау, гырлап йокыга китү.

**ЗАХРЕБЕ'ТНИК** *м.*, **ЗАХРЕБЕ'ТНИЦА** *ж. обл. устар.* — әрәм тамак.

**ЗАХРИПЕ'ТЬ** *сов. разг.* — хырылдый башлау.

**ЗАХРОМА'ТЬ** *сов.* — аксый башлау, аксаклый башлау.

**ЗАХРУСТЕ'ТЬ** *сов.* — шытырдый башлау, чатырдый башлау; чатырдап китү.

**ЗАХРЯ'СНУТЬ** *сов. обл.* — 1. кату; *грязь на морозе захрясла* — пычрак салкыннан каткан; 2. бүртү; *дверь захрясла и не отворяется* — ишек бүрткән, ачылмый; 3. бату, батып калу; *колёса захрясли в грязи* — тәгәрмәчләр пычракка батып калдылар.

**ЗАХУДА'ЛЫЙ** *книж.* — бөлгенлеккә төшкән, бөлгән, ярлы.

**ЗАХУДА'ТЬ** *сов. обл.* — бөлү, ярлылану.

**ЗАЦА'ПАТЬ** *сов. просторечь.* — 1. эләктерү, эләктереп алу; 2. (*поймать*) тотып алу, кулга алу, эләктереп алу.

**ЗАЦА'ПЫВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. зацапать.

**ЗАЦВЕСТИ'** *сов.* — чәчәк ата башлау; *зацвели яблони* — алмагачлар чәчәк ата башлады.

**ЗАЦВЕТА'ТЬ** *несов.* — к. зацвести.

**ЗАЦЕ'ПА** *ж. спец. обл.* — эләктергеч.

**ЗАЦЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. эләктерү, эләктереп алу; *зацепить багром* — багор белән эләктерү; 2. *перен. разг. устар.* чәнчү, төрттерү; *зацепить остротой* — тапкыр сүз белән төрттерү (чәнчү).

**ЗАЦЕПИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. эләгү; *платье зацепилось за гвоздь* — күлмәк кадакка эләкте; 2. тотыну, ябышу; *зацепиться за стол* — өстәлгә тотыну.

**ЗАЦЕ'ПКА** *ж. разг.* — 1. (*действие*) к. зацепить 1; 2. эләктергеч; 3. *перен. просторечь.* (*протекция*) таяныч, тотынып урын; 4. *перен. просторечь.* (*помеха*) тоткарлык, комачаулык.

**ЗАЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. зацепить.

**ЗАЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. зацепиться; 2. *страд.* эләктерелү, эләктереп алыну.

**ЗАЧАРОВА'ТЬ** *сов.* — 1. (*околдовать*) сихерләү; 2. *перен.* сокландыру, хәйран калдыру; исен китәрү, үзенә карату, ошау; *скрипач всех зачаровал своей музыкой* — скрипкачы үзенең уйнавы белән бөтен кешене сокландырды.

**ЗАЧАРО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. зачаровать.

**ЗАЧАСТИ'ТЬ** *сов. разг.* — ешайту, еш...-а башлау; *зачастить в гости* — кунакка еш йөри башлау. ◇ **Дождь зачастил** — яңгыр көчәеп китте.

**ЗАЧАСТУ'Ю** *нареч. разг.* — еш кына, еш-еш кына.

**ЗАЧА'ТОК** *м.* — 1. *биол.* яралгы, башлангыч, бәбәк, орлык; 2. *биол.* калдык (организмда элек булып та соңыннан бетүгә бара торган органның калдыгы); 3. *перен.* башлангыч, беренче күренеш; *зачатки новой жизни* — яңа тормышның беренче күренешләре.

**ЗАЧА'ТОЧНЫЙ** *книж.* — башлангыч хәлендәге, башлангыч (хәлендә булган); яралгы хәлендәге; *зачаточные органы* — яралгы хәлендәге органнар; *в зачаточном состоянии* — башлангыч хәлендә.

**ЗАЧА'ТЬ** *сов. устар.* — авырга узу, балага узу.

**ЗАЧА'ТЬСЯ** *сов. устар.* — 1. *книж. устар.* (*о зародыше*) барлыкка килү; 2. *обл. просторечь.* (*начаться*) башлану, башланып китү.

**ЗАЧА'ХНУТЬ** *сов.* — 1. (*о растениях*) корып бетү, кибеп бетү, сулып бетү; 2. (*о человеке*) кибеп бетү.

**ЗАЧЕ'М** *нареч.* — ни өчен, ник, нигә; *зачем пришёл?* — ник килдең?

**ЗАЧЕ'М-ТО** *нареч.* — ни өчендер, нигәдер, нәрсәгәдер.

**ЗАЧЕРВИ'ВЕТЬ** *сов.* — кортлау, кортлый башлау; *яблоко зачервивело* — алма кортлаган.

**ЗАЧЁРКИВАТЬ** *несов.* — к. зачеркнуть.

**ЗАЧЁРКИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сызылу, сызып ташлану.

**ЗАЧЕРКНУ'ТЬ** *сов.* — сызу, сызып ташлау; *зачеркнуть написанное* — язылганны сызып ташлау.

**ЗАЧЕРНЕ'ТЬ** *сов. разг.* — каралып күренә башлау; күренә башлау (кара әйбер турында); *вдали что-то зачернело* — еракта ниндидер кара нәрсә күренә башлады.

**ЗАЧЕРНЕ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— к. зачернеть.

**ЗАЧЕРНИ'ТЬ** *сов.*— каралту, карага буяу.

**ЗАЧЕРНЯ'ТЬ** *несов.*— к. зачернить.

**ЗАЧЕРНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — каралтылу, карага буялу.

**ЗАЧЕ'РПАТЬ** *сов. разг.*— чумырып ала башлау (суны); соса башлау (ашны).

**ЗАЧЕРПНУ'ТЬ** *сов.*— чумырып алу.

**ЗАЧЕРПНУ'ТЬСЯ** *сов. страд. разг.*— чумырып алыну.

**ЗАЧЕ'РПЫВАТЬ** *несов.*— к. зачерпнуть.

**ЗАЧЕ'РПЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. зачерпнуться.

**ЗАЧЁРСТВЕ'ЛЫЙ** — 1. искергән; каткан; *зачерствелый хлеб* — каткан (искергән) икмәк; 2. *перен.* суынган, тунган; *зачерствелое сердце* — суынган йөрәк, суынган күңел.

**ЗАЧЕРСТВЕ'ТЬ** *сов.* — 1. искерү, кату; *хлеб зачерствел* — икмәк искергән; 2. *перен.* суыну; *сердце зачерствело* — йөрәк суынды, күңел суынды.

**ЗАЧЕРТИ'ТЬ** *сов.* — 1. сызып тутыру, сызгалап бетерү; 2. *живоп.* сызгалап алу, өстән-өстән генә ясап ташлау (рәсемне); 3. *простореч. (зачеркнуть)* сызып ташлау.

**ЗАЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов.*— к. зачертить.

**ЗАЧЕСА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. *(начать чесать)* кашый башлау; 2. тарап кую; *зачесать волосы кверху* — чәчне артка таба тарап кую.

**ЗАЧЕСА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. кашына башлау; кычыта башлау; *у него зачесалась рука* — аның кулы кычыта башлады; 2. *(о волосах)* тарап куелу; тарап сыпырып куелу (чәч, артка таба яки бер якка).

**ЗАЧЕ'СТЬ** *сов.*— 1. исәпләү, исәбенә кертү; *зачесть сто рублей в уплату долга* — йөз сумны бурыч исәбенә кертү; *зачесть один год службы за два* — бер ел хезмәтне ике елга исәпләү; 2. зачёт кую; *преподаватель зачёл мою работу* — укытучы минем эшемә зачёт куйды.

**ЗАЧЕ'СТЬСЯ** *сов.*— исәпләнү, исәпкә алыну; *эта сумма зачтётся в счёт уплаты долга* — бу сумма бурычны түләүгә исәпләнер.

**ЗАЧЁСЫВАТЬ** *несов.*— к. зачесать 2.

**ЗАЧЁСЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. зачесаться 2.

**ЗАЧЁТ** *м.*— 1. *(действие)* к. зачесть; 2. зачёт; *поставить зачёт* — зачёт кую; *сегодня зачёт по истории* — бүген тарих буенча зачёт.

**ЗАЧЁТНЫЙ** — 1. исәпкә алу ...-ы; *зачётная квитанция* — исәпкә алу квитанциясе; 2. зачёт ...-ы; зачётлар ...-ы; *зачётная книжка* — зачёт кенәгәсе; *зачётная сессия* — зачётлар сессиясе.

**ЗАЧИ'Н** *м. лит.*—баш; *зачин пьесы*— пьесаның башы.

**ЗАЧИНА'ТЕЛЬ** *м. книж.* — башлаучы, башлап җибәрүче; *зачинатели колхозного движения* — колхоз хәрәкәтен башлап җибәрүчеләр.

**ЗАЧИНА'ТЬ** *несов.*— башлау, башлап җибәрү.

**ЗАЧИНА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. зачаться 2; 2. *страд.* башлап җибәрелү.

**ЗАЧИ'НИВАТЬ** *несов. разг.* — к. зачинить.

**ЗАЧИ'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— к. зачиниться.

**ЗАЧИНИ'ТЬ** *сов. разг.*— ямау, ямап кую; төзәтү, төзәтеп кую; *зачинить брюки* — чалбарны ямау.

**ЗАЧИНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ямалу, төзәтелү.

**ЗАЧИ'НЩИК** *м.*, **ЗАЧИ'НЩИЦА** *ж.* — башлап җибәрүче, башында торучы; котыртучы.

**ЗАЧИ'СЛИТЬ** *сов.*— 1. алу; *зачислить в институт*—институтка алу; 2. *бухг.* язып кую; *зачислить на текущий счёт 500 рублей* — агымдагы счётка 500 сум язып кую.

**ЗАЧИ'СЛИТЬСЯ** *сов.* — керү, алыну; *зачислиться в институт* — институтка керү (алыну).

**ЗАЧИСЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. зачислить.

**ЗАЧИСЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. зачислиться; 2. *страд.* язылу, язып куелу; *эта сумма зачисляется нами в счёт вашего долга* — бу сумма сезнең бирәнәгегез исәбенә языла.

**ЗАЧИ'СТИТЬ** *сов. простореч.* — чистартып тигезләү, шомарту, ялтырату.

**ЗАЧИТА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. уку, укып белдерү, укып игълан итү; *зачитать протокол* — протоколны уку; 2. *разг.* (укырга алып) кайтарып бирмәү; *он зачитал мою книгу* — ул минем китапны кайтарып бирмәде; 3. *(чтением вслух довести кого-н. до изнеможения)* озак укып арытып бетерү, укый-укый арытып бетерү; 4. укый-укый таушалдырып бетерү (китапны); 5. *(начать читать)* укый башлау.

**ЗАЧИТА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. онытылып уку, уку белән мавыгу (укырга бирелеп дөньяны онытү); 2. *(помешаться, слишком много читая)* укый-укый акылдан язу.

**ЗАЧИ'ТЫВАТЬ** I *несов.*— к. зачесть.

**ЗАЧИ'ТЫВАТЬ** II *несов. разг.*— к. зачитать 1, 2, 3, 4.

**ЗАЧИ'ТЫВАТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. зачесться; 2. *страд.* исәбенә кертелү, исәбенә кертеп саналу; зачёт куелу.

**ЗАЧИ'ТЫВАТЬСЯ** II *несов.*— 1. к. зачитаться; 2. *страд.* укылу, укып белдерелү, укып игълан ителү; күп укып таушалдырылу, укый-укый туздырып бетерелү (китап).

**ЗАЧИХА'ТЬ** *сов.*— төчкерә башлау.

**ЗАЧИЩА'ТЬ** *несов.*— к. зачистить.

**ЗАЧИЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— чистартып шомартылу, чистартып ялтыратылу.

**ЗАЧУ'ЯТЬ** *сов. разг.*— сизү, тою, сизеп алу.

**ЗАШАГА'ТЬ** *сов.*— атлый башлау; *зашагать к дому* — өйгә таба атлый башлау.

**ЗАША'РКАТЬ** *сов. разг.*—1. лаштыр-лоштыр атлап китү; 2. таптап бетерү; *весь пол*

*зашаркали* — бөтен идәнне таптап бетергәннәр.

**ЗАШАТА'ТЬ** *сов. разг.* — селкетә башлау. ◇ **Его зашатало** *безл.* — аның башы әйләнеп китте.

**ЗАШАТА'ТЬСЯ** *сов.* — селкенә башлау; *зуб зашатался* — теш селкенә башлады.

**ЗАШВЫРНУ'ТЬ** *сов. разг.* — атып бәрү, атып ташлау, тотып ату, ыргытып җибәрү.

**ЗАШВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. яудыру; *зашвырять камнями* — ташлар яудыру; 2. *(начать швырять)* ата башлау, ыргыта башлау.

**ЗАШВЫРЯ'ТЬСЯ** *сов. просторен.* — 1. *(начать швыряться)* ыргытыша башлау, атыша башлау; 2. ыргыта-ыргыта арып бетү.

**ЗАШЕВЕЛИ'ТЬ** *сов.* — кыймылдата башлау; *зашевелить пальцами* — бармакларны кыймылдата башлау.

**ЗАШЕВЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — хәрәкәткә килү, селкенә башлау, кыймылдый башлау; *листья зашевелились* — яфраклар селкенә башлады; *толпа зашевелилась* — халык төркеме хәрәкәткә килде.

**ЗАШЕЛЕСТЕ'ТЬ** *сов.* — кыштырдый башлау, шытырдый башлау; *на деревьях зашелестели листья* — агач яфраклары кыштырдый башлады.

**ЗАШЕЛУШИ'ТЬСЯ** *сов.* — куба башлау.

**ЗАШЕПТА'ТЬ** *сов.* — пышылдый башлау, пышылдап сөйли башлау.

**ЗАШЕПТА'ТЬСЯ** *сов.* — пышылдап сөйләшә башлау.

**ЗАШИБА'ТЬ** *несов. просторен.* — 1. к. зашибить; 2. *обл. (выпивать)* салырга ярату, эчәргә ярату. ◇ **Зашибать деньги** *вульг.* — акча төшерү.

**ЗАШИБА'ТЬСЯ** *несов. просторен.* — 1. к. зашибиться; 2. *страд.* бәрелү, сугылу, бәреп имгәтелү.

**ЗАШИБИ'ТЬ** *сов. разг.* — бәрү, бәреп имгәтү.

**ЗАШИБИ'ТЬСЯ** *сов. просторен.* — имгәнү, бәрелеп имгәнү.

**ЗАШИВА'ТЬ** *несов.* — к. зашить.

**ЗАШИВА'ТЬСЯ** I *несов.* — к. зашиться I.

**ЗАШИВА'ТЬСЯ** II *несов.* — к. зашиться II.

**ЗАШИПЕ'ТЬ** *сов.* — 1. *(о змее)* чыжылдый башлау, сызгыра башлау; 2. *(о гусях)* ыслый башлау; 3. *(о звуке брожения)* чыпырдый башлау; 4. *(о масле на сковороде)* чыжлый башлау.

**ЗАШИ'ТЬ** *сов.* — 1. ямау, ямап кую; 2. тегү, тегеп кую; *зашить посылку в холст* — посылканы киндергә тегеп кую.

**ЗАШИ'ТЬСЯ** I *сов. разг.* — тегелү, тегеп куелу.

**ЗАШИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — эләгү, кабу; утыру (кирәкмәс эш белән яки көч житмәслек эш белән).

**ЗАШИФРОВА'ТЬ** *сов.* — шифрлау, шифр белән язу (башка кеше укый алмаслык итеп, шартлы билгеләр белән язу).

**ЗАШИФРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. зашифровать.

**ЗАШИФРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — шифрлану, шифр белән язылу.

**ЗАШЛЁПАТЬ** *сов. разг.* — 1. *(начать шлёпать)* шапылдата башлау; 2. *(пойти, шлёпая)* лаштыр-лоштыр китеп бару.

**ЗАШНУРОВА'ТЬ** *сов.* — шнурлау, шнур белән бәйләү, шнур белән бәйләп кую.

**ЗАШНУРОВА'ТЬСЯ** *сов.* — шнурлану, шнур белән бәйләнү, шнур белән бәйләп куелу.

**ЗАШНУРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. зашнуровать.

**ЗАШНУРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. зашнуроваться.

**ЗАШПАКЛЕВА'ТЬ** *сов.* — шпаклевать итү, сылап тигезләп кую; *зашпаклевать щели* — ярыкларны шпаклевать итү.

**ЗАШПАКЛЕВА'ТЬСЯ** *сов.* — шпаклевать ителү, сылап куелу.

**ЗАШПАКЛЁВЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. зашпаклевать.

**ЗАШПАКЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. зашпаклеваться.

**ЗАШПИ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. зашпилить.

**ЗАШПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. зашпилиться.

**ЗАШПИ'ЛИТЬ** *сов.* — шпилька кадап кую, булавка кадап кую; *зашпилить волосы* — чәчкә шпилька кадап кую.

**ЗАШПИ'ЛИТЬСЯ** *сов.* — шпилька кадап куелу, булавка кадап куелу.

**ЗАШТА'ТНЫЙ** *устар.* — штаттан тыш. ◇ **Заштатный город** *устар.* — өяз үзәге булмаган шәһәр (патша Россиясендә).

**ЗАШТЕМПЕЛЕВА'ТЬ** *сов.* — штемпель басу, штемпель сугу.

**ЗАШТЕМПЕЛЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. заштемпелевать.

**ЗАШТО'ПАТЬ** *сов.* — штопать итү.

**ЗАШТО'ПАТЬСЯ** *сов. разг.* — штопать ителү.

**ЗАШТРИХОВА'ТЬ** *сов.* — штриховать итү.

**ЗАШТУКАТУ'РИВАТЬ** *несов.* — к. заштукатурить.

**ЗАШТУКАТУ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — к. заштукатуриться.

**ЗАШТУКАТУ'РИТЬ** *сов.* — штукатурлау, штукатурлап чыгу; *заштукатурить стены* — стеналарны штукатурлау.

**ЗАШТУКАТУ'РИТЬСЯ** *сов.* — штукатурлану.

**ЗАШТУКОВА'ТЬ** *сов. порт.* — җөе беленмәслек итеп тегү.

**ЗАШТУКО'ВЫВАТЬ** *несов. порт.* — к. заштуковать.

**ЗАШТУКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. порт.* — җөе беленмәслек итеп тегелү.

**ЗАШУМЕ'ТЬ** *сов.* — тавыш күтәрү, шаулый башлау; *дети зашумели* — балалар шаулый башлады.

**ЗАШУРША'ТЬ** *сов.* — кыштырдый башлау; *зашуршали камыши* — камышлар кыштырдый башлады.

**ЗАШУШУ'КАТЬСЯ** *сов. разг.* — пыш-пыш сөйләшә башлау.

**ЗАЩЕБЕТА'ТЬ** — черелди башлау; *защебетали птицы* — кошлар черелди башлады.

**ЗАЩЕКОТА'ТЬ** I *сов. разг.* — 1. *(замучить щекоткой)* кытыклап хәлдән тайдыру, кытыклап интектерү; 2. *(начать щекотать)* кытыклый башлау.

**ЗАЩЕКОТА'ТЬ** II *сов. обл.* — чут-чут итеп сайрый башлау; *соловей защекотал* — сандугач чут-чут итеп сайрый башлады.

**ЗАЩЁЛКА** *ж.* — 1. *(часть замка)* йозак теле; 2. *обл. (щеколда)* келә, капка келәсе.

**ЗАЩЁЛКАТЬ** *сов.* — 1. чутылдый башлау, чут-чут итеп сайрый башлау; *соловей защёлкал* — сандугач чут-чут итеп сайрый башлады; 2. шартлата башлау; *защёлкать кнутом* — чыбыркы шартлата башлау; *защёлкать пальцами* — бармак шартлата башлау; 3. *(каблуками* и т. п.) шалт итеп бәрү (аякны аякка); 4. *(начать грызть семечки, орехи)* шарт-шорт вата башлау.

**ЗАЩЕЛКА'ТЬ** *сов. разг.* — чиертеп йөдәтеп бетерү.

**ЗАЩЁЛКИВАТЬ** *несов. разг.* — к. защелкнуть.

**ЗАЩЁЛКИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. защелкнуться.

**ЗАЩЁЛКНУТЬ** *сов. разг.* — шалт итеп бикләү, шалт итеп ябып кую.

**ЗАЩЁЛКНУТЬСЯ** *сов. разг.* — шалт итеп бикләнү, шалт итеп ябылу.

**ЗАЩЕМИ'ТЬ** *сов.* — кыстыру, кыстырып кую; *защемить проволоку клещами* — тимер чыбыкны келәшчә белән кыстырып кую; *защемить палец* — бармакны кыстыру. ◇ **Защемило на сердце** — йөрәгем чәнчешә башлады. **Защемило грудь** — күкрәгем кыса башлады.

**ЗАЩЕМЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. защемить.

**ЗАЩЕМЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — кысылу; кыстырылу.

**ЗАЩИПА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. чеметә башлау; 2. *(волосы, перья* и т. д.) йолкый башлау; 3. *(измучить щипками)* чеметкәләп интектереп бетерү.

**ЗАЩИПНУ'ТЬ** *сов. разг.* — кыстырып алу, эләктереп алу (кыскыч белән); чеметеп алу.

**ЗАЩИПНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кыстырып алыну, эләктереп алыну (кыскыч белән).

**ЗАЩИ'ПЫВАТЬ** *несов. разг.* — 1. к. защипнуть; 2. к. защипать.

**ЗАЩИ'ПЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. защипнуться.

**ЗАЩИ'ТА** *ж. мн.* нет — 1. *(действие)* к. защищать; 2. арка таянычы, терәк, таяныч; *сын — моя защита* — улым — минем таянычым; 3. *собир. юр.* яклаучылар, яклаучы як (адвокатлар); *свидетели защиты* — яклаучы як шаһитлары; 4. *собир. спорт.* защита (саклаучылар); *защита играла хорошо* — защита яхшы уйнады; 5. саклагыч, саклый; *зонтик — защита от дождя и солнца* — зонтик янгырдан һәм кояштан саклый.

**ЗАЩИТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — яклау ...-ы; *защитительная речь* — яклау рече.

**ЗАЩИТИ'ТЬ** *сов.* — к. защищать 1, 2.

**ЗАЩИТИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. защищаться.

**ЗАЩИ'ТНИК** *м.* — 1. *(заступник)* яклаучы; 2. *юр.* защитник, яклаучы.

**ЗАЩИ'ТНИЦА** *ж.* — к. защитник 1.

**ЗАЩИ'ТНЫЙ** — 1. саклый торган; *защитные очки* — күзләрне саклый торган күзлек; 2. *воен.* соргылт яшел; *сукно защитного цвета* — соргылт яшел төстәге сукно; 3. ышыклау ...-ы; *защитные лесные полосы* — ышыклау урман полосалары.

**ЗАЩИЩА'ТЬ** *несов.* — 1. *(оборонять)* саклау; 2. *(предохранять)* саклау, каплау, ышыклау; 3. яклау, яклап чыгу.

**ЗАЩИЩА'ТЬСЯ** *несов.* — саклану.

**ЗАЯВИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ЗАЯВИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. офиц.* — 1. белдерүче, килеп әйтүче; 2. заявка бирүче.

**ЗАЯВИ'ТЬ** *сов.* — 1. белдерү, әйтү, хәбәр итү; 2. *устар.* раслату; *заявить доверенность у нотариуса* — доверенностьны нотариустан раслату. ◇ **Заявить себя** *книж.* — үзен күрсәтү, үзен таныту.

**ЗАЯВИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — килеп керү, килеп чыгу, кайтып керү; *заявился в первом часу ночи* — төнге сәгать беренчедә килеп керде.

**ЗАЯ'ВКА** *ж.* — заявка.

**ЗАЯВЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. белдерү; *правительственное заявление* — хөкүмәт белдерүе; 2. гариза, заявление; *подать заявление* — заявление бирү.

**ЗАЯВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. заявить.

**ЗАЯВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. заявиться; 2. *страд.* белдерелү, хәбәр ителү, әйтелү.

**ЗАЯ'ВЩИК** *м.*, **ЗАЯ'ВЩИЦА** *ж.* — к. заявитель.

**ЗАЯ'ДЛЫЙ** *разг.* — хирес, бик нык бирелгән, ...-га яратучан; *заядлый игрок* — хирес уенчы, уйнарга яратучан кеше; *заядлый спорщик* — бәхәсләшергә яратучан кеше.

**ЗАЯСНИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *обл.* ачыла башлау, аязлана башлау (һава); 2. *книж. поэт.* ялтырап күренә башлау, җемелдәп күренә башлау.

**ЗА'ЯЦ** *м.* — 1. куян; *(заячий мех)* куян тиресе; 2. *перен. разг.* билетсыз пассажир.

**ЗА'ЯЧИЙ** — куян ...-ы; куян тиресеннән тегелгән; *заячья шкура* — куян тиресе; *заячья шуба* — куян тиресеннән тегелгән тун; ◇ **Заячья душа** — куркак, куян йөрәк.

**ЗА'ЯЧИНА** *ж. мн.* нет, *обл.* — куян ите.

**ЗВА'НИЕ** *ср.* — 1. исем; *звание Героя Социалистического Труда* — Социалистик Хезмәт Герое исеме; 2. звание; *звание капитана* — капитан званиесе; 3. *устар.* сословие, катлау, дәрәҗә; *тут были люди всякого звания* — монда төрле сословие кешеләре бар иде.

**ЗВА'НЫЙ** *разг.* — 1. чакырылган; *званые гости* — чакырылган кунаклар; 2. чакырулы, тантаналы; *званый обед* — чакырулы (тантаналы) аш мәҗлесе.

**ЗВАТЬ** *несов.* — 1. (*приглашать*) чакыру; 2. (*называть*) атау, исемләү. ◇ **Как тебя звать?** — синең исемең ничек? **Поминай, как звали** — җилләр исте, әзе дә калмады, әсәре дә калмады.

**ЗВА'ТЬСЯ** *несов. разг. устар.* — аталу, исемләнү.

**ЗВЕЗДА'** *ж.* — 1. *астр.* йолдыз; 2. *перен.* иң күренекле кеше, талант иясе; *звезда театра* — театрның иң күренекле артисты. ◇ **Он звёзд с неба не хватает** *разг. ирон.* — акылга таман кеше, уртача кеше. **Верить в свою звезду** — үз бәхетеңә ышану.

**ЗВЕЗДАНУ'ТЬ** *сов. простореч. вульг.* — ялтыратып җибәрү, чалтыратып җибәрү, яңагына менеп төшү.

**ЗВЕЗДИ'СТЫЙ** — 1. йолдызлы; *звездистое небо* — йолдызлы күк; 2. *спец.* йолдызсыман; 3. *перен.* нурлы, йолдыздай, йолдыз кебек; *звездистые очи* — нурлы күзләр.

**ЗВЕЗДИ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — җемелдәү, җемелдәп тору; *небо звездится* — күк җемелдәп тора.

**ЗВЁЗДНЫЙ** — 1. *астр.* йолдызлар ...-ы; *звёздная система* — йолдызлар системасы; 2. йолдызлы, йолдызлар белән капланган; *звёздная ночь* — йолдызлы төн.

**ЗВЕЗДОПА'Д** *м. обл.* — йолдызлар атылу вакыты (көз көне).

**ЗВЕЗДОЧЁТ** *м. устар.* — к. астролог.

**ЗВЕНЕ'ТЬ** *несов.* — шалтырау, шылтырау, чылтырау, шыңгырату; *звенит колокольчик* — кыңгырау шалтырый. ◇ **В ушах (или в ухе) звенит** *разг.* — колагым шаулый (шаулап тора), колагым чыңлап тора.

**ЗВЕНО'** *ср.* (*мн.* звенья) — 1. (*в цепи*) буын, бощра; 2. *перен.* буын, бүлек (бөтен бер нәрсәнең состав өлеше); *низшее звено советского аппарата* — совет аппаратының түбәнге буыны; 3. звено; *садоводческая бригада состоит из двух звеньев* — бакчачылык бригадасы ике звенодан тора.

**ЗВЕНЬЕВО'Д** *м.* — звено башлыгы, звено җитәкчесе.

**ЗВЕНЬЕВО'Й** — 1. звено ...-ы; звенолар ...-ы; *звеньевая система* — звено(лар) системасы. 2. звено башлыгы, звено җитәкчесе.

**ЗВЕРЁНОК** *м.* (*мн.* зверята) *разг. фам.* — җәнлек баласы, ерткыч хайван баласы.

**ЗВЕРЁНЫШ** *м. разг.* — к. зверёнок.

**ЗВЕРЕ'ТЬ** *несов.* — ерткычлану, кансызлану.

**ЗВЕРИ'НЕЦ** *м.* — зверинец (ерткыч җанварларны, җәнлекләрне халыкка күрсәтү өчен саклау урыны).

**ЗВЕРИ'НЫЙ** — 1. җәнлек ...-ы, ерткыч хайван ...-ы; *звериные следы* — җәнлек эзләре; 2. *перен.* ерткычларча ..., ерткычлык ...-ы; *звериная ненависть* — ерткычларча нәфрәт; 3. *перен.* рәхимсез, каты; *звериные законы капитализма* — капитализмның рәхимсез законнары.

**ЗВЕРОБО'Й** I *м. книж. устар.* — аучы.

**ЗВЕРОБО'Й** II *м. бот.* — сары мәтрүшкә.

**ЗВЕРОБО'ЙНЫЙ** I — җәнлек аулау ...-ы; ерткыч хайваннар аулау ...-ы; *зверобойный промысел* — җәнлек аулау промыселы.

**ЗВЕРОБО'ЙНЫЙ** II *бот.* — сары мәтрүшкә ...-ы; *зверобойные семена* — сары мәтрүшкә орлыклары.

**ЗВЕРОВО'Д** *м.* — җәнлек асрау белгече, җәнлек асраучы.

**ЗВЕРОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — җәнлек үрчетү, җәнлек асраучылык.

**ЗВЕРОВО'ДЧЕСКИЙ** — җәнлек үрчетү ...-ы; *звероводческое хозяйство* — җәнлек үрчетү хуҗалыгы.

**ЗВЕРОЛО'В** *м.* — җәнлек аулаучы.

**ЗВЕРОЛО'ВНЫЙ** — җәнлек аулау ...-ы; *звероловный промысел* — җәнлек аулау промыселы.

**ЗВЕРОЛО'ВСТВО** *ср. мн.* нет — җәнлек аулау промыселы.

**ЗВЕРОПОДО'БНЫЙ** — ерткыч хайванга охшаган.

**ЗВЕ'РСКИ** *нареч.* — 1. рәхимсез рәвештә, аяусыз рәвештә; *зверски избили* — рәхимсез рәвештә кыйнап ташлаганнар; 2. *разг.* эт кебек, бик нык; *зверски устал* — эт кебек арыдым.

**ЗВЕ'РСКИЙ** — 1. ерткычларча ...; аяусыз; *зверское убийство* — ерткычларча үтерү; 2. *разг.* бик көчле, бик зур; *у него зверский аппетит* — аның аппетиты бик зур.

**ЗВЕ'РСТВО** *ср. книж.* — ерткычлык, вәхшилек, кансызлык, рәхимсезлек.

**ЗВЕ'РСТВОВАТЬ** *несов.* — ерткычлану, ерткычларча кылану, кансызлану, явызлану.

**ЗВЕРЬ** *м.* — 1. (*хищное животное*) ерткыч, ерткыч хайван; (*нехищное, дикое животное*) җәнлек, кыргый хайван; 2. *перен.* (*о человеке*) кансыз, явыз, ерткыч. ◇ **Зверь зверем** — ерткыч кебек; *накинулся на меня зверь-зверем* — өстемә ерткыч кебек ташланды.

**ЗВЕРЬЁ** *ср. собир. мн.* нет, *разг.* — ерткыч хайваннар; җәнлекләр.

**ЗВОН** *м.* — 1. (*действие*) к. звонить; 2. шалтырау; шалтырау тавышы; чылтырау, шыңгырдау; *звон колокола* — кыңгырау шалтыравы; 3. *перен. простореч.* (*сплетни*) гайбәт, сүз.

**ЗВОНА'РЬ** *м.* — 1. *церк.* чиркәүдә чаң кагучы; 2. *перен.* (*сплетник, болтун*) гайбәтче, лыгырдык, такылдык.

**ЗВОНИ'ТЬ** *несов.* — 1. шалтырату; кагу; *звонить в колокол* — кыңгырау шалтырату; чаң кагу; 2. шалтырау, чалтырау; *колокол звонит* — кыңгырау шалтырый; *телефон звонит* — телефон шалтырый; 3. шалтырату; *я звонил ему* — мин аңа шалтыраттым; 4. *перен. разг. фам.* (*разглашать, сплетничая*) гайбәт тарату.

**ЗВОНИ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — звонок бирү, шалтырату.

**ЗВО'НКИЙ** — 1. яңгыравыклы, яңгыравык; *звонкий колокол* — яңгыравыклы кыңгырау; *звонкие голоса* — яңгыравык

тавышлар; 2. *лингв.* яңгырау ..., яңгыравыклы; *звонкие согласные* — яңгырау тартыклар. ◇ **Звонкая монета** — вак акча, металл акча.

**ЗВО'НКО** *нареч.* — яңгыратып.

**ЗВОНКОГОЛО'СЫЙ** *книж. устар.* — яңгыравык тавышлы.

**ЗВО'НКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — яңгыравыклык, яңгырап тору.

**ЗВОНО'К** *м.* — 1. звонок (прибор); 2. (*звуковой сигнал*) звонок тавышы, звонок.

**ЗВО'НЧАТЫЙ** *обл.* — тавышлы, яңгыравыклы, яңгыравыклы тавышлы.

**ЗВУК** *м.* — 1. тавыш; 2. *лингв.* аваз; *гласные звуки* — сузык авазлар. ◇ **Пустой звук** — буш сүз, мәгънәсез сүз. **Ни звука** — 1. тып-тын; *в лесу ни звука* — урман тып-тын; 2. тынын да чыгармый; *зову его, а он ни звука* — мин аны чакырам, ә ул тынын да чыгармый.

**ЗВУКОВО'Й** — 1. тавыш ...-ы; *звуковые волны* — тавыш дулкыннары; 2. тавышлы; *звуковое кино* — тавышлы кино.

**ЗВУКОПОДРАЖА'НИЕ** *ср. лингв.* — 1. тавышка охшату (мәсәлән, мәче тавышы — мияу-мияу); 2. тавыш ияртемнәре, тавышка охшатып ясалган сүз (мәсәлән, күке, кыштырдау һ. б. сүзләр).

**ЗВУКОПОДРАЖА'ТЕЛЬНЫЙ** — тавышка охшатып ясалган; *звукоподражательное слово* — тавышка охшатып ясалган сүз.

**ЗВУКОПРОВО'ДНЫЙ** *физ.* — тавыш үткәрә торган.

**ЗВУКОУЛОВИ'ТЕЛЬ** *м.* — тавыштоткыч.

**ЗВУЧА'НИЕ** *ср. мн.* нет — яңгырау.

**ЗВУЧА'ТЬ** *несов.* — 1. яңгырау, яңгырап тору, ишетелү; *колокол звучит* — кыңгырау яңгырый; 2. *перен.* сизелеп тору, беленеп тору; *в его голосе звучала радость* — аның тавышында шатлык сизелеп тора иде.

**ЗВУ'ЧНО** *нареч.* — яңгырап, яңгыратып.

**ЗВУ'ЧНОСТЬ** *ср. мн.* нет — 1. ачыклык, яңгыравыклылык, көчлелек; 2. тулы тавышлылык, тулы аһәңлелек.

**ЗВУ'ЧНЫЙ** — ачык яңгыравыклы, көчле тавышлы; *звучный оркестр* — көчле тавышлы оркестр.

**ЗВЯ'КАТЬ** *несов. разг.* — шалтырату, чылтырату; шалтырау, чылтырау.

**ЗВЯ'КНУТЬ** *сов.* — 1. шалтыратып кую, чылтыратып кую; 2. *разг.* (*по телефону*) шалтырату.

**ЗГИ:** **не видно ни зги** — дөм-караңгы, күзгә төртсәң күренмәс.

**ЗДА'НИЕ** *ср.* — 1. бина, йорт; 2. *перен.* система, нигез.

**ЗДЕСЬ** *нареч.* — 1. (*тут*) монда, биредә; 2. шунда; шул чакта; *здесь он кашлянул* — шул чакта ул йөткереп куйды; 3. *перен.* бу эштә; *здесь я ничем не могу помочь* — бу эштә мин бернн белән дә ярдәм итә алмыйм.

**ЗДЕ'ШНИЙ** *разг.* — мондагы, биредәге.

**ЗДОРО'ВАТЬСЯ** *несов.* — исәнләшү, күрешү.

